**САРДА'Р** *м.*—сәрдар (1. кайбер Якын Көнчыгыш илләрендә коралны көчләр башлыгы; 2. Һиндстанда һәм Афганстанда кабилә башлыгы, зур түрә).

**САРДЕ'ЛЬ** и **САРДЕ'ЛЬКА** *ж.*— 1. *устар.* к. сардинка; 2. сарделька (сосисканың бер төре).

**САРДИ'НА** и **САРДИ'НКА** *ж.*— сардина (1. сельдь семьялыгыннан булган вак диңгез балыгы; 2. шул балыктан хәзерләнгән консерв).

**САРДОНИ'КС** *м.*—сардоникс (ахакның бер төре, чуар катламлы асылташ).

**САРДОНИ'ЧЕСКИЙ** — усал, чәнечкеле, ачы, зәһәрле, мыскыл итеп...; *сардонический смех* — усал көлү.

**СА'РЖА** *ж.*— саржа (кием эчлегенә китә торган тукыманың бер төре).

**СА'РЖЕВЫЙ** — 1. саржа ...-ы; *саржевое производство* — саржа производствосы; 2. саржа(дан тегелгән); *саржевая подкладка* — саржа эчлек.

**САРКА'ЗМ** *м. книж.*— сарказм (1. ачы көлү, зәһәрле көлү, агулы көлү; 2. шундый замечание).

**САРКА'НИТЬ** *сов. обл.*— аркан белән тоту, арканлау.

**САРКАСТИ'ЧЕСКИЙ** *м. книж.* —сарказмлы, саркастик, чәнечкеле, агулы, зәһәрле, усал; *саркастический тон* — саркастик тон.

**САРКО'МА** *ж. мед.*— яман шеш, саркома.

**САРКОФА'Г** *м. истор.*— саркофаг, таш табут.

**САРМА'ТКА** *ж. истор.*— сармат хатынкызы.

**САРМА'ТСКИЙ** — сармат ...-ы; *сарматские племена* — сармат кабиләләре.

**САРМА'ТЫ** *мн. истор.*— сарматлар (безнең эрага кадәр 6—4 гасырлардан башлап Кара диңгез буендагы далаларда яшәгән иран кабиләләре группасы. Безнең эраның 4 гасырында гуннарның һөҗүменә дучар булганнар).

**САРПИ'НКА** *ж.*— сарпинка, сәрфинкә.

**САРПИ'НКО'ВЫЙ** — сарпинка...; *сарпинковое платье* — сарпинка күлмәк.

**САРПИНОТКА'ЦКИЙ** — сарпинка туку ...-ы; *сарпиноткацкая промышленность*— сарпинка туку промышленносте.

**САРПИ'НОЧНИК** *м. спец.*— сарпинка тукучы, сарпинка производствосында эшләүче.

**САРЫ'НЬ** *ж. обл.*: **сарынь на кичку** — корабль борынына китегез (элек Иделдә юлбасарлар корабльне талаганда аның экипажына шулай дип кычкырганнар, имеш).

**САРЫ'Ч** *м. зоол.*— сарыча (карчыганың бер төре).

**САРЫ'ЧА** *ж. зоол. обл.*— к. сарыч.

**САТАНА'** *м. мн.* нет — 1. иблис; 2. *зоол.* сатана (Америка маймылларының бер төре).

**САТАНЕ'ТЬ** *несов. разг.*— к. осатанеть 1.

**САТАНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — 1. *религ.* иблискә табыну; 2. *перен.* сатанизм (романтикларда һәм декадентларда явыз көчләргә баш ию).

**САТАНИ'НСКИЙ** *книж. рел.*—иблис...-ы; *сатанинское наваждение* — иблис вәсвәсәсе; 2. *перен.* гаять дәрәҗәдә явыз; *сатанинская злоба* — гаять дәрәҗәдә явыз ачу.

**САТАНИ'ЧЕСКИЙ** *книж. устар.*— к. сатанинский.

**САТЕЛЛИ'Т** *м.*— сателлит (1. *астр.* планета иярчене; 2. *перен. книж. ритор. полит.* империалистик дәүләтләрнең кушканын үтәүчеләр; 3. *физ.* ачык спектраль сызык белән янәшә баручы тонык спектраль сызык).

**САТИ'Н** *м.*— сатин (тукыма).

**САТИНЕ'Т** *м.*— юка сатин.

**САТИНЕ'ТОВЫЙ** — юка сатин(нан тегелгән); *сатинетовая рубаха* — юка сатин күлмәк.

**САТИНИ'РОВАТЬ** *несов. спец.*— сатиндай ялтырату, сатин кебек итеп ялтырату.

**САТИНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— ялтыратылу, сатиндай ялтыратылу, сатин төсле ялтыравыклы ителү.

**САТИНИРО'ВЩИК** *м. спец.*—ялтыратучы, сатин кебек итеп ялтыратучы.

**САТИ'НОВЫЙ** — сатин(нан тегелгән); *сатиновая рубаха* — сатин күлмәк.

**САТИ'Р** *м.*— сатир (1. борынгы грекларда койрыклы, мөгезле, кәҗә аягысыман аяклы мифик зат; 2. *перен.* азгын, бозык, зиначы кеше).

**САТИ'РА** *ж. лит.*— сатира (1. *лит.* тор-

мышның кире якларын ачы көлеп сурәтләгән әдәби әсәр; 2. *перен.* мыскыллап көлү).

**САТИ'РИК** *м. лит.* — сатирик, сатирик әсәрләр язучы.

**САТИРИ'ЧЕСКИЙ** — сатира ...-ы, сатирик; *сатирическая литература* — сатира әдәбияты.

**САТРА'П** *м.* — сатрап (1. борынгы Иранда патшаның провинциядәге тулы властьлы наместнигы; 2. *перен.* явыз түрә, башбаштак түрә).

**САТРА'ПИЯ** *ж. истор.* — сатрапия (сатрап карамагындагы өлкә).

**САТУРА'ТОР** *м. тех.* — сатуратор (сатурация ясау приборы).

**САТУРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *тех.* — сатурация (1. сатурацияләү, сатурация ясау, сыекчаны газ белән туендыру; 2. шикәр сыекчасын известь белән чистартканнан соң артык булган известьне аерып алу).

**САТУРНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — сатурнизм (кайбер зарарлы производстволарда кургаш белән агулану).

**САФЬЯ'Н** *м.* — сәхтиян (кәҗә тиресеннән ясалган югары сыйфатлы күн).

**САФЬЯ'НОВЫЙ** — сәхтиян...; сәхтияннан ясалган; сәхтияннан тегелгән; *сафьяновые сапоги* — сәхтиян итек.

**СА'ХАР** *м.* — 1. шикәр; 2. *перен. просторечь. ирон.* төче телле, тәмле телле кеше. ◇ **Сахар-медович** *разг.* — ялагай, төче телле кеше. **Чәй да сахар** *просторечь. фам.* — тәмле булсын чәегез. **Постный сахар** — кайнаткан шикәр (конфетның бер төре).

**САХАРИ'МЕТР** *м. спец.* — сахариметр (эремәдә шикәрнең процентын билгеләү приборы).

**САХАРИ'Н** *м. мн.* нет — сахарин.

**САХАРИ'НОВЫЙ** — сахарин...-ы; *сахариновый порошок* — сахарин порошогы.

**САХАРИ'НЩИК** *м. спец.* — сахарин ясаучы, сахарин производствосында эшче.

**САХАРИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет — шикәрлелек; *сахаристость свеклы* — чөгендернең шикәрлелеге.

**САХАРИ'СТЫЙ** — 1. шикәр кебек, шикәр төсле; 2. шикәрле; *сахаристые вещества* — шикәрле матдәләр.

**СА'ХАРИТЬ** *несов.* — шикәр салу, шикәр кушу, шикәр сибү, шикәрләү.

**СА'ХАРИТЬСЯ** *несов.* — шикәрләнү.

**СА'ХАРНИК** *м.* — шикәрче, шикәр промышленносте эшчесе.

**СА'ХАРНИЦА** *ж.* — шикәр савыты.

**СА'ХАРНЫЙ** — 1. шикәр...-ы; *сахарная промышленность* — шикәр промышленносте; 2. *перен.* ялагай, төче; *сахарные речи* — ялагай сүзләр; 3. *перен.* шикәр..., шикәр кебек тәмле, шикәрдәй татлы; *сахарные уста* — шикәрдәй татлы иреннәр, шикәр ирен; 4. *перен.* шикәр кебек ак, шикәрдәй; *сахарная белизна снега* — карның шикәрдәй аклыгы. ◇ **Сахарный клещ** *зоол.* — шикәр бете. **Сахарная болезнь** — к. диабет.

**САХАРОВА'Р** *м. спец.* — шикәр кайнатучы.

**САХАРОВАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — шикәр кайнату.

**САХАРОВАРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — шикәр кайната торган; *сахароварительный котёл* — шикәр кайната торган казан.

**САХАРОВА'РНЫЙ** *спец.* — шикәр кайнату...-ы; *сахароварное дело* — шикәр кайнату эше.

**САХАРОВА'РНЯ** *ж. устар.* — шикәр кайнату заводы.

**САХАРО'ЗА** *ж. хим.* — сахароза (үсемлекләр составында була торган шикәр).

**САХАРОЗАВО'ДЧИК** *м.* — шикәр заводы хуҗасы.

**САХАРОНО'С** *м. спец.* — шикәр үсемлеге (шикәр алырга мөмкин булган үсемлек, мәсәлән, чөгендер, шикәр камышы).

**САХАРОНО'СНЫЙ** — шикәр бирә торган; *сахароносные растения* — шикәр бирә торган үсемлекләр.

**САЧИ'ТЬ** *несов. спец.* — сөкә белән тоту (балыкны).

**САЧО'К** *м.* — сөкә.

**САШЕ'** *ср. нескл. устар.* — 1. хушбуйланган кечкенә мендәр; 2. кечкенә сумка (кулъяулыклар салу өчен).

**СБА'ВИТЬ** *сов.* — 1. киметү, төшерү; *сбавить полкило* — ярты килога киметү; *сбавить цену* — хакын төшерү; 2. кимү; *сбавить в весе* — авырлыгы кимү.

**СБА'ВИТЬСЯ** *сов. просторечь.* — к. убавиться.

**СБА'ВКА** *ж. разг.* — 1. к. сбавить, сбавляться; 2. киметелгән өлеш, скидка, ташлама.

**СБАВЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. сбавить.

**СБАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. *несов.* к. сбавиться; 2. *страд.* киметелү, төшерелү.

**СБА'ГРИТЬ** *сов. просторечь.* — 1. к. ба́грить; 2. *фам.* котылу (мәсәлән, теңкәгә тигән кунактан).

**СБАЛАНСИ'РОВАТЬ** *сов. бухг.* — к. балансировать 2.

**СБА'ЛТЫВАТЬ** *несов. просторечь.* — к. сболтать.

**СБА'ЛТЫВАТЬСЯ** *несов. просторечь.* — болтатылу.

**СБЕ'ГАТЬ** *сов. разг.* — йөгереп барып кайту, йөгереп барып килү, тиз генә барып килү.

**СБЕГА'ТЬ** *несов.* — к. сбежать.

**СБЕГА'ТЬСЯ** *несов.* — к. сбежаться.

**СБЕЖА'ТЬ** *сов.* — 1. йөгереп төшү; *сбежать с лестницы* — баскычтан йөгереп төшү; 2. агып төшү; *с окрестных гор уже снега сбежали мутными ручьями на потопленные луга* (Пушкин) — тирә-яктагы таулардагы карлар болганчык гөрләвекләр булып су баскан болыннарга агып төштеләр; 3. качу; *сбежать из плена* — пленнан качу; 4. качу, качып китү, югалу; *сбежала собака от хозяина* — эт иясеннән качып киткән; 5. *перен. разг. фам. шутл.* качу, качып китү, ташлап качу, таю; *сбежать с работы* — эштән качып китү; 6. төсе китү, уңу, буявы бетү; *краска сбежала с сукна* — постауның төсе уңган; 7. *спец.* та-

шып бетү, ташып түгелеп бетү; *весь навар сбежал* — өресе ташып түгелеп беткән.

**СБЕЖА'ТЬСЯ** *сов.*— (төрле яктан) йөгереп килеп жыелу.

**СБЕРЕГА'ТЕЛЬ** *м. канц. устар.*— акчасын сакка салучы, (берәр нәрсә) саклаучы.

**СБЕРЕГА'ТЕЛЬНЫЙ** *офиц.*— саклык...-ы; *сберегательная касса* — саклык кассасы.

**СБЕРЕГА'ТЬ** *несов.*— к. сберечь.

**СБЕРЕГА'ТЬСЯ** *несов.*— к. сберечься.

**СБЕРЕЖЕ'НИЕ** *ср.*—1. *(действие)* к. сберечь; 2. (саклап) жыелган акча, жыйган акча.

**СБЕРЕ'ЧЬ** *сов.*— 1. саклау, саклап калу, саклап алып калу; *сберечь документы* — документларны саклап алып калу; 2. саклап жыеп кую, саклыкка жыеп кую.

**СБЕРЕ'ЧЬСЯ** *сов.*— сакланып калу.

**СБЕРКА'ССА** *(сберегательная касса) ж. разг.*— саклык кассасы.

**СБЕРКНИ'ЖКА** *(сберегательная книжка) ж.*— саклык кенәгәсе.

**СБЕСИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. взбеситься.

**СБИВА'ТЬ** *несов.*— к. сбить.

**СБИВА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. сбиться; 2. *перен. разг.* охшау; *рассказ сбивается на сказку* — хикәя әкияткә охшый.

**СБИ'ВЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — буталчык булу, буталчыклык, каршылыклы булу.

**СБИ'ВЧИВЫЙ** — буталчык, каршылыклы.

**СБИР** *м.*— сбир (1. *истор.* Италиядә инквизициянең иң түбән дәрәҗәле хезмәткәре; 2. Италиядә полиция стражнигы; 3. *перен.* полиция шымчысы).

**СБИРА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. собирать.

**СБИРА'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. собираться.

**СБИ'ТЕНЩИК** *м. устар.*— ширбәт сатучы.

**СБИ'ТЕНЬ** *м. мн.* нет, *устар.*— ширбәт (бал ширбәте).

**СБИТЬ** *сов.*— 1. сугып төшерү; бәреп төшерү; *сбить шляпу* — эшләпәне бәреп төшерү; 2. бәреп вату, сугып өзү; *сбить замок* — йозакны бәреп вату; 3. кыйшайту; *сбить каблуки*— үкчәләрне кыйшайту; 4. бәреп чыгару, куып чыгару; *сбить противника с позиции*—дошманны позициясеннән бәреп чыгару; 5. *воен.* атып төшерү, бәреп төшерү; *сбить самолёт* — самолётны атып төшерү; 6. *(повалить)* сугып егу, бәреп егу; 7. (юлдан, сукмактан) яздыру; *сбить с тропинки* — сукмактан яздыру; 8. *перен.* аптыраштa калдыру, юлдан яздыру, бутау; *сбить с толку* — аптыраштa калдыру; 9. *простореч.* бору, икенчегә бору (сүзне, фикерне); 10. *перен. (убавить)* киметү; 11. ясау, жыеп ясау; бергә жыю, жыю; *сбить ящик из досок* — такталардан ящик ясау; 12. *разг.* киметү, кимегә төшү, киметергә мәҗбүр итү; *сбить спесь* — тәкәбберлеген кимәтә төшү; *сбить цену* — бәясен кимәтә төшү; 13. язу, атлау; *сбить масло* — май язу; 14. күпертү, туглау; *сбить белки* — йомырка агын күпертү; 15. *разг.* куып бер жиргә жыю; *сбить гончих* — ау этләрен куып бер жиргә жыю. ◇ **Сбить лезвие ножа** — пычакның йөзен үтмәсләү. **Сбить подковы** — дагаларны шомартып бетерү.

**СБИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. янтаю, кыйшаю; *шляпа сбилась на бок* — эшләпә кыйшайган, эшләпә янтайган; 2. *спец.* үтмәсләнү; *лезвие бритвы сбилось* — бритваның йөзе үтмәсләнгән; 3. оешу; *тюфяк сбился* — түшәк оешкан; 4. кыйшаю, тапталып кыйшаю; *каблуки сбились* — үкчәләр кыйшайган; 5. адашу, юлдан язу; *я сбился в потемках с дороги* — караңгыда мин юлдан яздым; *сбились мы* — без адаштык; 6. ялгышу; *сбиться со счёта* — санаганда ялгышу; 7. ялгышу, аптырап калу, буталу; *читая стихи, ученик сбился* — шигырь укыганда укучы буталды; 8. *(скучиться)* жыелу, жыелышу, өелешү. ◇ **Масло хорошо сбилось** — май яхшы язылган. **Сбиться с толку** — аптырап калу, ялгышу, юлдан язу. **Сбиться с ног** — хәлдән таю. **Перед финишем рысак сбился** *спец. спорт.*— финишка килеп житкәндә юртак ыргый башлады.

**СБЛЕВА'ТЬ** *сов. простореч. вульг.*— косу, косып чыгару.

**СБЛИЖА'ТЬ** *несов.*— к. сблизить.

**СБЛИЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. сблизиться; 2. *страд.* якынайтылу, якын китерелү, якынлаштырылу.

**СБЛИ'ЗИТЬ** *сов.*—1. (бер-беренә) якынайту, якын китерү; *сблизить ножки циркуля* — җәзбәнең аяkларен бер-беренә якынайту; 2. *перен.* якынлаштыру, дуслаштыру; *общие интересы их сблизили* — гомуми интереслар аларны якынлаштырды; 3. *перен. книж.* чагыштыру, охшашлыкны ачу; *сблизить понятия* — төшенчәләрне чагыштыру.

**СБЛИ'ЗИТЬСЯ** *сов.*— 1. якынлашу, (бер-беренә) якын килү; 2. *перен.* дус булып китү, дуслашып китү; *мы сблизились очень скоро* — без бик тиз дуслашып киттек.

**СБЛОКИ'РОВАТЬСЯ** *сов. разг.*— к. блокироваться 1.

**СБО'ЧИНА** *ж. обл.*— түп (орлыктан май чыгарганнан соң калган түп).

**СБОИ'ТЬ** *несов. спец. спорт.*— юртканда ыргый башлау (ат турында).

**СБОЙ** *м. спец.*—1. *только ед.* баш-аяк һәм үпкә-бавыр (суелган терлекнең); 2. вак салам (ашлык сукканда калган вак салам, башак һ. б.); 3. *спорт.* ыргу, сикерү (ат юртканда ыргый башлау).

**СБО'КУ** *нареч.*— кырыйдан, яннан, бер яктан, читтән. ◇ **Сбоку припёка** — һич урынсызга, бер дә юкка.

**СБОЛТА'ТЬ** *сов. простореч.*—1. к. взболтать; 2. болгатып кушу (бер сыекчаны икенче сыекча белән).

**СБОЛТИ'ТЬ** *сов. тех.*— болт белән тоташтыру.

**СБОЛТНУ'ТЬ** I *сов. простореч.*— к. сболтать.

**СБОЛТНУ'ТЬ** II *сов. разг. неодобр.*— әйтеп салу, сүз ычкындыру, сүз ычкындырып җибәрү, әйтеп ташлау.

**СБО'ЛЧИВАТЬ** *несов. тех.*— к. сболтить.

**СБО'ЛЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. тех.*— болт белән тоташтырылу.

**СБО'НДИТЬ** *сов. просторең. вульг.*— чәлдерү (урлау).

**СБОР** *м.*—1. жыю; *сбор снопов* — көлтәләр жыю; **2.** салым, налог, жыем; *все сборы уплачены* — барлык салымнар түләнгән; 3. җыелу; *сбор демонстрантов* — демонстрантларның җыелуы; **4.** *воен.* сбор; *ехать на сбор* — сборга бару; **5.** *только мн.* әзерлек, җыену; *сборы к путешествию* — сәяхәткә китәргә җыену; **6.** *обл.* к. сборка 2. ◇ **Все в сборе** — барысы да җыелган.

**СБО'РИСТЫЙ** *обл.*— к. сборчатый.

**СБО'РИЩЕ** *ср. пренебр.*— зур җыен, халык төркеме.

**СБО'РКА** *ж.*—1. җыю, кору; *сборка машин* — машиналарны җыю; 2. бөрмә; *платье со сборками* — бөрмәле күлмәк.

**СБО'РНИК** *м.*— җыентык; *сборник статей* — мәкаләләр җыентыгы.

**СБО'РНЫЙ** —1. җыелма; *сборная команда* — җыелма команда; 2. төрле ...-дан ...-тан; *сборная уха* — төрле балыклардан пешерелгән балык шулпасы; **3.** аерым кисәкләрдән җыйналган; *сборный механизм* — аерым кисәкләрдән җыйналган механизм; **3.** *тех.* җыелма, җыелмалы; *сборные здания* — җыелма биналар. ◇ **Сборный пункт**— җыелу пункты.

**СБО'РОЧНЫЙ** *спец.*— җыю...-ы, җыйнау...-ы; *сборочная мастерская* — җыю мастерское.

**СБО'РЧАТЫЙ** — бөрмәле; *сборчатый передник* — бөрмәле алъяпкыч.

**СБО'РЩИК** *м.*, **СБО'РЩИЦА** *ж.*— җыючы; *сборщик профсоюзных взносов* — профсоюз взносларын җыючы.

**СБРА'СЫВАТЬ** *несов.*— к. сбросить.

**СБРА'СЫВАТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. сброситься; **2.** *страд.* ташлану, алып ташлану; 3. *страд.* кәрәп төшерелү; **4.** *страд.* чигерелү, алып ташлану (счётта).

**СБРЕДА'ТЬ** *несов. обл.*— к. сбрести.

**СБРЕДА'ТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— к. сбрестись.

**СБРЕ'ДИТЬ** *сов. просторең.*—**1.** саташканда әйтү; **2.** *перен. презрит.* алдау, ялганлау, уйлап чыгару.

**СБРЕ'НДИТЬ** *сов. просторең. презрит.*— **1.** ялганлау, ялган сөйләү; **2.** ахмак сүз әйтеп кую.

**СБРЕСТИ'** *сов. обл.*— китү, читкә китү.

**СБРЕСТИ'СЬ** *сов.*— (төрле яктан килеп) җыелу, акрынлап җыелу.

**СБРЕХА'ТЬ** *сов. просторең. презрит.*— к. сбрехнуть.

**СБРЕХНУ'ТЬ** *сов. просторең. презрит.*— (явыз ниятсез) ялганлау, ялганлап кую.

**СБРИВА'ТЬ** *несов.*— к. сбрить.

**СБРИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— (бритва белән) кырып алыну, кырып ташлану.

**СБРИ'ТЬ** *сов.*— **1.** (бритва белән) кырып алу, кырып ташлау, кыру; *сбрить бороду* — сакалны кырып ташлау; **2.** *(ловко украсть)* сөртү, чәлдерү.

**СБРОД** *м. мн.* нет, *собир.*— к. подонки 2.

**СБРОДИ'ТЬ** *сов. спец.*— әчү, әчеп җитү.

**СБРО'ДНЫЙ** *просторең. пренебр.*— аннан-моннан җыелган; җыен юк-бар кешеләр...-ы; *сбродная компания*—аннан-моннан җыелган компания (җыен юк-бар кешеләр төркеме).

**СБРОСА'ТЬ** *сов. просторең.*— ташлап бетерү.

**СБРО'СИТЬ** *сов.*— **1.** ташлау; *сбросить груз на землю* — йөкне җиргә ташлау; **2.** төшерү, ташлау; *сбросить снег с крыши*— өй түбәсеннән кар ташлау; **3.** егып төшерү; күтәреп бәрү; **4.** төшерү, ташлау; *сбросить воздушный десант* — һавадан десант төшерү; **5.** *(снять с себя)* салу; **6.** к. сбавить 1; **7.** *экон.* (базарга) күпләп чыгару; **8.** *перен.* алып ташлау, бәреп төшерү, бетерү; *сбросить иго самодержавия* — самодержавие изүен алып ташлау; **9.** *(на счетах)* алып ташлау, чигерү.

**СБРО'СИТЬСЯ** *сов.*— ташлану; *сброситься с моста* — күпердән ташлану.

**СБРОШЮРОВА'ТЬ** *сов.*— к. брошюровать.

**СБРУ'Я** *ж. мн.* нет, *собир.*— сбруй, дирбия (ат җигү әйберләре).

**СБРЫ'ЗГИВАТЬ** *несов. разг.*— к. сбрызнуть.

**СБРЫ'ЗНУТЬ** *сов. разг.*— бөркү, бөркеп алу; *сбрызнуть бельё водой* — кергә су бөркеп алу.

**СБУЛГА'ЧИТЬ** *сов. просторең.*— к. булгачить.

**СБЫВА'ТЬ** *несов.*— к. сбыть.

**СБЫВА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. сбыться; **2.** *страд.* сатылу, сатып җибәрелү.

**СБЫТ** *м. мн.* нет, *торг. экон.*— сату.

**СБЫТОВО'Й** — сату...-ы; *сбытовые операции* — сату операцияләре.

**СБЫ'ТОЧНЫЙ** *обл. разг.*— булуы мөмкин булган, була ала торган.

**СБЫ'ТЧИК** *м. разг.*— сатучы (күбесенчә урланган әйбер сатучы).

**СБЫТЬ** *сов.*—**1.** *торг.* *(продать)* сату; **2.** *(избавиться)* котылу, кулдан җибәрү; **3.** *(пойти на убыль)* кимү.

**СБЫ'ТЬСЯ** *сов.*—**1.** *(осуществиться)* тормышка ашу; **2.** *устар.* *(случиться, произойти)* булу.

**СВА'ДЕБНЫЙ** — туй...-ы; *свадебные песни* — туй җырлары. ◇ **Свадебный генерал** *устар.*— туй генералы (туйга шөһрәт өчен чакырылган генерал).

**СВА'ДЬБА** *ж.*— туй. ◇ **До свадьбы заживёт** *разг. шутл.*—ямавы өстендә, төзәлер; ямавы өстендә, туйга хәтле төзәлер (берәр җирен яралаган кеше турында шаярып әйтелә). **На Маланьину свадьбу (напечь, настряпать)** *просторең.*— тиле кызның туена җитәрлек (бик күп ашамлык пешерү турында).

**СВАЕБО'ЕЦ** *м.*— субай кагучы.

**СВА'ЙКА** *ж.*— свайка (**1.** зур кадакны ыргытып, очлы башын җирдә яткан божраның уртасына туры китереп төшерүдән гыйбарәт уен; **2.** шул уенда кулланыла торган кадак).

**СВА'ЙНЫЙ** —**1.** субай кагу...-ы; *свайные работы* — субай кагу эшләре; **2.** субайлар өстенә корылган; *свайная постройка* — субайлар өстенә корылган каралты.

**СВАЛ** *м. простореч.*— к. свалка 1.

**СВА'ЛИВАТЬ** *несов.*—1. к. валить 1; 2. *разг.* к. свалить I во 2 знач; 3. *охот.* к. свалить 5.

**СВА'ЛИВАТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. свалиться; 2. *страд.* төшерелү, ишеп төшерелү, аударылу.

**СВА'ЛИВАТЬСЯ** II *несов. разг.*— к. сваляться.

**СВАЛИ'ТЬ** I *сов.*—1. төшерү, ишеп төшерү; *свалить снег с крыши* — түбәдән карны ишеп төшерү; 2. аудару, егу; *ветер свалил дерево* — җил агачны аударган; 3. аяктан егу; *болезнь свалила его* — авыру аны аяктан екты; 4. бәреп төшерү; *свалить самодержавие* — самодержавиене бәреп төшерү; 5. аудару, ташлау; *свалить работу на другого* — эшне башка кеше өстенә ташлау; 6. аудару; бушату; *свалить дрова в кучу* — утынны бер өемгә аудару; 7. сылтау, аудару; *свалить вину на другого* — гаепне икенче кешегә сылтау; 8. *охот.* бергә җибәрү, өер итеп җибәрү; *свалить две стаи гончих* — ике өер ау этләрен бергә җибәрү.

**СВАЛИ'ТЬ** II *сов. разг.*— кимү, басылу; *жар свалил, повеяла прохлада* — эссе басылды, салкын җил исә башлады.

**СВАЛИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. ишелеп төшү; *снег свалился с крыши* — түбәдән кар ишелеп төште; 2. егылып төшү; *свалился в канаву* — канауга егылып төште; 3. аву; *дерево свалилось* — агач ауды; 4. *(обессилев, заболеть)* авырып киту, аяктан егылу; 5. *перен. разг.* төшү; *свалилась на меня забота* — минем өскә мәшәкать төште; 6. *(о судах)* бәрелешү; 7. *охот.* өерелешү, өергә кушылу (ау этләре турында).

**СВА'ЛКА** *ж.*—1. *(действие)* к. свалить I в 1 и 8 знач.; 2. тиреслек, чүплек, чүплек башы; *выбросить на свалку* — чүплеккә чыгарып ташлау; 3. тәртипсез рәвештә өелгән әйберләр; 4. *(беспорядочная драка)* өймәкләшеп сугышу, кыйнашу.

**СВА'ЛЬНЫЙ** —1. чүп-чар ташлана торган; *свальное место* — чүп-чар ташлана торган урын; 2. йөк бушатыла торган; *свальная пристань* — йөк бушатыла торган пристань; 3. *простореч. устар.* өймәкләшеп... көрмәкләшеп...; *свальная драка* — өймәкләшеп сугышу.

**СВАЛЯ'ТЬ** *сов.*—1. басу, басып кую; *свалять валенки* — киез итек басу; 2. әвәләү, әвәләп ясау; *свалять игрушку из глины* — әвәләп балчыктан уенчык ясау; *сделал не как следует, а свалял* — рәтләп эшләмәгән, әвәләп кенә куйган. ◇ **Свалять дурака** — к. дурак.

**СВАЛЯ'ТЬСЯ** *сов.*—1. басылу; *валенки хорошо свалялись* — киез итекләр яхшы басылган; 2. чуалу, киезләнү; *у лошади грива свалялась* — атның ялы киезләнгән.

**СВА'НСКИЙ** — сван...-ы; *сванский язык* — сван теле.

**СВА'НЫ** *мн.*— сваннар, сван халкы (Грузиянең көнбатышында яшәүче халык).

**СВА'РА** *ж. простореч.*— талаш, гауга, ызгыш.

**СВАРГА'НИТЬ** *сов. простореч.*— ничек житте шулай эшләү; ашык-пошык эшләп ташлау; миннән киткәнче, иясенә җиткәнче дип эшләп ташлау.

**СВА'РИВАЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *тех.*— металларның кыздырып ябыштырыла алуы.

**СВА'РИВАТЬ** *несов. тех.*— к. сварить 3.

**СВА'РИВАТЬСЯ** *несов. тех.*— 1. к. свариться 3; 2. кыздырып ябыштырылу.

**СВАРИ'ТЬ** *сов.*—1. пешерү, пешереп алу; *сварить кашу* — ботка пешереп алу; 2. кайнату, кайнатып алу; *сварить клею* — җилем кайнатып алу; 3. кыздырып ябыштыру, сварка ясап ябыштыру; *сварить два куска железа* — ике тимер кисәген кыздырып ябыштыру. ◇ **Каши** или **пива не сваришь** — к. каша.

**СВАРИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. пешү, пешеп җитү; *суп сварился* — аш пеште; 2. к. перевариться 2; 3. *тех.* кызып ябышу, сварка ярдәмендә ябышу.

**СВА'РКА** *ж. тех.*— сварка, кыздырып ябыштыру (металлны).

**СВАРЛИ'ВЕЦ** *м.*, **СВАРЛИ'ВИЦА** *ж.*— мыгырдык кеше, сукранучан кеше.

**СВАРЛИ'ВОСТЬ** *ж.*— бәйләнчеклек, тиргәшергә яратучанлык.

**СВАРЛИ'ВЫЙ** — ызгышучан, тиргәшергә яратучан, бәйләнчек; *сварливый характер* — бәйләнчек характер.

**СВАРНО'Й** и *устар.*, **СВА'РНЫЙ** — кыздырып ябыштырылган; *сварной шов* — кыздырып ябыштырылган җөй.

**СВА'РОЧНЫЙ** *тех.*—1. сварка ясау...-ы, кыздырып ябыштыру...-ы; *сварочный цех* — кыздырып ябыштыру цехы; 2. кыздырып ябыштырылган; *сварочное железо* — кыздырып ябыштырылган тимер.

**СВА'РЩИК** *м.*— сварщик (металлны кыздырып ябыштыручы эшче).

**СВА'СТИКА** *ж.*— свастика (1. *этнол.* борынгы Һиндстанда очлары бөгелгән тәре төсле дини символик билге; 2. фашистлар эмблемасы).

**СВАТ** *м.*—1. яучы, димче; 2. кода. ◇ **Ни брат, ни сват** — кардәшем түгел, якын кешем түгел.

**СВА'ТАНЬЕ** *ср. мн.* нет, *простореч.*— к. сватовство.

**СВА'ТАТЬ** *несов.*—1. кодалау, яучылау; 2. *перен. простореч. шутл.* тәкъдим итү, димләү; *сватают нам нового человека* — безгә яңа бер кеше димлиләр.

**СВА'ТАТЬСЯ** *несов.*—1. кодалау; 2. кода җибәрү, димче җибәрү.

**СВАТОВСТВО'** *ср. мн.* нет — кодалау, димләү, яучылау.

**СВА'ТУШКА** *м. простореч. обл.*— яучыкай, кодакай. ◇ **Сватушки мои** *разг.*— атакаем, әй ходаем!

**СВА'ТЬЯ** *ж. обл.* —кодагый, кодача.

**СВА'ХА** *ж.* — яучы (хатын-кыз).

**СВА'Я** *ж.* — субай.

**СВЕВА'ТЬ** *несов. книж.* — к. свеять.

**СВЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — к. свеиваться.

**СВЕ'ДАТЬ** *сов. устар. обл.* — белү, белешү, хәбәр алу.

**СВЕ'ДАТЬСЯ** *сов. устар. обл.* — алдан сөйләшеп кую, сүз куешу.

**СВЕДЕ'НЕЦ** *м. устар.* — (мәҗбүри рәвештә) күчерелгән кеше, күчереп утыртылган кеше.

**СВЕ'ДЕНИЕ** *ср.* — **1.** хәбәр, белдерү; *по сведениям печати* — матбугат хәбәрләренә караганда; **2.** белү, танышу, искә алу; *принять к сведению* — искә алу; **3.** *только мн.* белемнәр; *человек с большими сведениями по математике* — математикадан зур белемнәре булган кеше; **4.** *канц.* мәгълүмат; *представить сведения* — мәгълүмат бирү. ◇ **Довести до всеобщего сведения** — бөтен кешегә белдерү, бөтен кешегә игълан итү.

**СВЕДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* —**1.** (*действие*) к. свести (6, 7, 8 мәгънәләреннән башкалары); **2.** (*судорожное сжатие мышц*) тартышу, көзән җыеру.

**СВЕ'ДУЩИЙ** — тирән белемле, мәгълүматлы; *сведущий учёный* — тирән белемле галим.

**СВЕЖА'ТИНА** *ж. мн.* нет, *обл.* — яңа ит, яңа суйган ит.

**СВЕЖЕВА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — эчен арчучы, тиресен тунаучы (суйган терлекнең).

**СВЕЖЕВА'ТЬ** *несов. спец.* — тиресен тунау һәм эчен арчу (суйган терлекнең).

**СВЕЖЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — тиресе туналу һәм эче тазартылу, эче арчылу (суйган терлекнең).

**СВЕЖЕИСПЕЧЁННЫЙ** — **1.** яңа пешкән, яңа гына пешеп чыккан, яңа гына пешерелгән; *свежеиспечённый хлеб* — яңа гына пешерелгән икмәк; **2.** (*новенький*) өр-яңа. ◇ **Свежеиспечённый студент** — яңа гына студент булган кеше. **Свежеиспечённый врач** — яңа гына врач булган кеше.

**СВЕЖЕНИ'НА** *ж. мн.* нет, *обл.* — к. свежина.

**СВЕЖЕПРОСО'ЛЬНЫЙ** *спец.* — яңа гына тозланган; күптән түгел генә тозланган.

**СВЕ'ЖЕСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** яңалык; *свежесть мыслей* — фикерләрнең яңалыгы; 2. (*прохлада*) салкынчалык, җиләслек. ◇ **Не первой свежести** — 1) бик үк яңа (свежий) түгел; 2) *перен. шутл. ирон.* бик үк яшь түгел; *она не первой свежести* — ул бик үк яшь түгел.

**СВЕЖЕ'ТЬ** *несов.* — 1. (*становиться холоднее*) салкынчалану, җиләсләнү, салкыная төшү; 2. (*становиться румянее, здоровее*) тазарып китү, яшәреп китү, тазара төшү.

**СВЕ'ЖИЙ** — 1. яңа...-ган, яңа гына...-ган; (хәзер генә...-ган, әле генә...-ган); *свежие фрукты* — яңа өлгергән җимешләр; *свежее молоко* — яңа сауган сөт; *свежее яйцо* — яңа салган йомырка; *свежее сено* — яңа чапкан печән; *свежая зарубка на дереве* — агачта яңа гына ясалган уем; *свежий след зайца* — яңа гына үткән куян эзе; *свежее варенье* — яңа кайнаткан варенье; **2.** саф, таза, чиста, салкын, салкынча, рухландыра торган, күңел күтәрә торган; *свежий воздух* — саф һава; *свежий ветерок* — салкынча җил; *умыться свежей водой* — салкын су белән юыну; **3.** (*о погоде*) салкын; *на дворе свежо* — тышта салкын; **4.** *мор.* шактый көчле; *свежий ветер* — шактый көчле җил; *свежая волна* — шактый көчле дулкын; **5.** *только полн. формы* яңа; *сварить свежего чаю* — яңа чәй салып пешерү; **6.** *разг.* чиста, яңа, юылган; *свежие воротнички* — яңа якалар; *свежая сорочка* — юылган күлмәк; **7.** *перен.* әйбәт, яхшы, ачык төстәге; *свежий цвет лица* — әйбәт чырай; *свежие краски* — ачык төстәге буяулар; **8.** *перен.* яңа; *свежая мысль* — яңа фикер; *прибыли свежие войска* — яңа гаскәрләр килде; *со свежими силами* — яңа көч белән (ял иткәннән соң); **9.** *перен.* саф; *встал со свежей головой* — саф баш белән тордым; **10.** *перен.* таза, яшь чырайлы; *у него свежий вид* — ул яшь чырайлы. ◇ **Свежо предание, а верится с трудом** — яңа хәбәр, ләкин ышануы читен. **Свежо в памяти** — әле дә истә тора, әле дә онытылмаган.

**СВЕЖИ'НА** *ж. обл. мн.* нет — тозланмаган ит; тозланмаган балык.

**СВЕЗТИ'** *сов.* — 1. илтү, илтеп кую; *свезти в Москву* — Мәскәүгә илтү; 2. *простореч.* алып барып кайту; *свезти детей в театр* — балаларны театрга алып барып кайту; **3.** төшерү, алып төшү; *свезти с горы* — таудан төшерү; 4. алып китү; *свезти мусор на свалку* — чүп-чарны чүплеккә алып китү; 5. *простореч.* кузгатып алып китү; *свезти с места воз* — йөкне урыныннан кузгатып алып китү; **6.** *простореч. фам. шутл.* тартып төшерү; *свезти скатерть со стола* — эскәтерне өстәлдән тартып төшерү.

**СВЕЗТИ'СЬ** *сов. постореч.* — төшү, шуып төшү.

**СВЕ'ИВАТЬ** *несов. книж.* — к. свеять.

**СВЕ'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — өреп төшерелү.

**СВЁКЛА** *ж. мн.* нет — чөгендер; *свёкла кормовая* — мал чөгендере (терлекләргә ашату өчен үстерелә торган чөгендер); *свёкло сахарная* — шикәр чөгендере; *свёкла столовая* — аш чөгендере.

**СВЕКЛОВИ'ЦА** *ж. мн.* нет — шикәр чөгендере.

**СВЕКЛОВИ'ЧНЫЙ** — **1.** шикәр чөгендере...-ы; *свекловичные поля* — шикәр чөгендере кырлары; **2.** шикәр чөгендере үстерә торган; *свекловичный совхоз* — шикәр чөгендере үстерә торган совхоз; **3.** (*добываемый из свекловицы*) шикәр чөгендереннән алына торган.

**СВЕКЛОВО'Д** *м. спец.* — чөгендер үстерүчелек белгече, чөгендер үстерүче.

**СВЕКЛОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — чөгендер үстерү, (промышленность өчен) чөгендер үстерүчелек.

**СВЕКЛОВО'ДЧЕСКИЙ** — чөгендер үстерү...-ы; *свекловодческий совхоз* — чөгендер үстерү совхозы.

**СВЕКЛОКОМБА'ЙН** *м. с.-х.* — чөгендер комбайны.

**СВЕКЛОКОПА'ТЕЛЬ** *м. с.-х.* — чөгендер казыгыч (машина).

**СВЕКЛОМО'ЙКА** *ж. с.-х.* — чөгендер югыч, чөгендер юу машинасы.

**СВЕКЛОПОДЪЁМНИК** *м. с.-х.* — чөгендер алгыч (чөгендер казып алу машинасы).

**СВЕКЛОРЕ'ЗКА** *ж. с.-х.* — чөгендер турагыч, чөгендер кискеч, чөгендер турау машинасы.

**СВЕКЛОСА'ХАРНЫЙ** — **1.** шикәр чөгендере үстерә торган; *свекловахарные поля* — шикәр чөгендере үстерә торган басулар; **2.** шикәр чөгендере эшкәртү...-ы; *свеклосахарное производство* — шикәр чөгендере эшкәртү производствосы.

**СВЕКЛОСОВХО'З** *м.* — чөгендер үстерү совхозы.

**СВЕКЛОУБО'РКА** *ж. мн.* нет, *с.-х. спец.* — чөгендер җыю, чөгендер җыеп алу.

**СВЕКЛОУБО'РОЧНЫЙ** *с.-х.* — чөгендер җыя торган; *свеклоуборочная машина* — чөгендер җыя торган машина.

**СВЕКСВА'ТЬ** *сов.* — к. вековать.

**СВЕКО'ЛЬНИК** *м.* — **1.** чөгендер ашы; **2.** (*свекольная ботва*) чөгендер сабагы.

**СВЕКО'ЛЬНЫЙ** — чөгендер...-ы; *свекольный лист* — чөгендер яфрагы.

**СВЁКОР** *м.* — каенатa, биатa.

**СВЕКРО'ВКА** *ж. обл.* — к. свекровь.

**СВЕКРО'ВЬ** *ж.* — каенана, биана.

**СВЕЛИКОДУ'ШНИЧАТЬ** *сов. разг.* — киң күңеллеләнеп ташлау.

**СВЕРБЁЖ** *м. мн.* нет — кычыту, кымыржу.

**СВЕРБЕ'ТЬ** *несов. простореч.* — кычыту, әчетеп кычыту, кымыржу.

**СВЕРГА'ТЬ** *несов.* — к. свергнуть.

**СВЕРГА'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** *книж. устар.* к. свергнуться; **2.** *страд.* бәреп төшерелү.

**СВЕ'РГНУТЬ** *сов.* — **1.** *книж. устар.* аудару, аударып төшерү; **2.** *перен.* төшерү, бәреп төшерү; *свергнуть царя* — патшаны бәреп төшерү.

**СВЕ'РГНУТЬСЯ** *сов. книж. устар.* — егылып төшү; *свергнуться с балкона* — балконнан егылып төшү.

**СВЕРЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. свергнуть.

**СВЕ'РЗИТЬ** *сов. разг. шутл. презрит.* — төшерү, төртеп төшерү.

**СВЕ'РЗИТЬСЯ** *сов. разг. шутл. презрит.* — егылып төшү.

**СВЕ'РИТЬ** *сов.* — чагыштыру, чагыштырып тикшерү, чагыштырып чыгу.

**СВЕ'РИТЬСЯ** *сов.* — тикшерү, тикшереп белү; белешмә алу.

**СВЕ'РКА** *ж.* — **1.** чагыштыру, чагыштырып тикшерү, барлау; **2.** *тип.* соңгы корректура.

**СВЕРКА'ТЬ** *несов.* — балку, ялтырау, ялтйолт итү. ◇ **Молния сверкает** — яшен яшьни. **Только пятки сверкают** — к. пятка.

**СВЕРКНУ'ТЬ** *сов. однокр.* — **1.** ялт итеп китү, ялтырап китү; *звезда сверкнула и погасла* — йолдыз ялт итеп китте дә сүнде; **2.** *перен.* кинәт башка килү, кинәт искә төшү; *сверкнула мысль* — кинәт башка бер уй килде.

**СВЕРЛИ'ЛЬНЫЙ** — бораулау ...-ы; *сверлильный станок* — бораулау станогы.

**СВЕРЛИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — бораулаучы.

**СВЕРЛИ'ТЬ** *несов.* — **1.** бораулау, бораулап тишү; *сверлить доску* — тактаны бораулау; **2.** *простореч.* тишү; *червяк сверлит древесину* — корт үзагачны тишә; **3.** *перен.* чәнчешеп авырту, чәнчешү; *боль сверлит сердце* — йөрәгем чәнчешеп авырта; *сверлит в ухе* — колагым чәнчешә. ◇ **Эта мысль сверлит мой мозг** — шул фикер миңа һичбер тынычлык бирми.

**СВЕРЛИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — бораулану, бораулап тишелү.

**СВЕРЛО'** *ср.* — **1.** борау; **2.** *спец.* (*жало у насекомых*) ук.

**СВЕРЛО'ВОЧНЫЙ** *тех.* — к. сверлильный.

**СВЕРЛО'ВЩИК** *м.*, **СВЕРЛО'ВЩИЦА** *ж.* — к. сверлильщик.

**СВЁРНУТЫЙ** — **1.** төрелгән, уралган; *ноты, свёрнутые трубкой* — трубкасыман итеп төрелгән ноталар; **2.** киметелгән, кыскартылган; *штаты свёрнуты* — штатлар кыскартылган; **3.** (*загнувшийся*) бөгелгән, бөрешкән.

**СВЕРНУ'ТЬ** *сов.* — **1.** төреп кую, төрү; *свернуть ковёр* — паласны төреп кую; *свернуть ноты в трубку* — ноталарны трубкасыман итеп төреп кую; *свернуть цыгарку* — тәмәке төрү; **2.** йому, йомып кую; *цветы свернули лепестки* — чәчәкләр таҗ яфракчыкларын йомдылар; **3.** *воен. офиц.* киметү, кыскарту, тарайту; *свернуть фронт* — фронтны кыскарту; *свернуть производство* — производствоны кыскарту; **4.** борылып керү, борылып китү, читкә китү; *свернуть с дороги в лес* — юлдан урманга борылып керү; **5.** *перен. разг.* бору (сүзне, фикерне); *опять свернул на прежнее* — сүзне тагын әүвәлгегә борды; **6.** *разг.* борып вату, борып бозу; *свернуть ключ* — ачкычны борып вату. ◇ **Свернуть голову** (или **шею**) *разг.* — 1) муенын бору; *свернуть голову цыплёнку* — чебинең муенын бору; 2) *перен. фам.* муенын сындыру; *я этому негодяю голову сверну* — мин ул кабахәтнең муенын сындырырмын.

**СВЕРНУ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** бөтерелү, бөрешү; *лист свернулся и засох* — яфрак бөрешеп кипкән; **2.** йомарлану, бөгәрләнү; *кошки свернулись клубочком на печке* — мәчеләр йомгак кебек йомарланып мич башында яталар; **3.** ою; *кровь свернулась* — кан оеды; **4.** эрү; *молоко свернулось* — сөт эреде; **5.** кысылу, кимү, тараю; *производство свернулось* — производство кыскарды; *фронт свернулся* — фронт тарайды (кыскарды); **6.** *простореч.* бора-бора ватылу; *ключ свернулся* — ачкыч бора-бора ватылган; **7.** *разг.* аву; каплану; *санки свернулись* — чана ауган.

**СВЕРСТА'ТЬ** *сов.* — **1.** *тип.* версткалау, биткә салу (типографиядә наборны битләргә салу); **2.** *устар. обл.* тигезләү; *сверстать гряды* — түтәлләрне тигезләү.

**СВЕРСТА'ТЬСЯ** *сов. устар. обл.* — тигезләнү.

**СВЕ'РСТНИК** *м.*, **СВЕ'РСТНИЦА** *ж.* — яшьтәш.

**СВЕ'РСТНИЧЕСТВО** *ср. книж.* — яшьтәшлек.

**СВЁРСТЫВАТЬ** *несов.* — к. сверстать.

**СВЁРСТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. сверстаться; 2. *страд.* версткалану, биткә салыну (типографиядәге набор).

**СВЕРТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. к. свернуть 1, 6; 2. (*вертя снять*) борып алу, борып чыгару.

**СВЕРТЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — борыла-борыла сыры бетү, күп борудан бозылу.

**СВЁРТКА** *ж. обл.* — к. свёрток 2.

**СВЁРТОК** *м.* — 1. төргәк, төенчек; 2. (*поворот дороги*) борылма, юл борылышы, юл чаты.

**СВЁРТЫВАТЬ** — к. свернуть, свертеть.

**СВЁРТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. свернуться, свертеться; 2. *страд.* төрелү.

**СВЕРХ** *предлог с род. п.* — 1. өстеннән, өстенә; *сверх полушубка* — тун өстеннән; 2. тыш; *сверх плана* — планнан тыш; 3. (*кроме, помимо*)...-дан тыш,...-дан башка; *сверх зарплаты* — эш хакыннан башка. **Сверх того** — шуның өстенә, өстәвенә.

**СВЕРХВЫСО'ТНЫЙ** — гадәттән тыш биек (стратосферада, субстратосферада очуга бәйләнгән).

**СВЕРХДРЕДНО'УТ** *м. мор.* — зур дредноут (зур сугыш корабле).

**СВЕРХКОМПЛЕ'КТ** *м. мн.* нет, *воен.* — комплекттан артык, комплекттан тыш (нәрсә).

**СВЕРХКОМПЛЕ'КТНЫЙ** — комплекттан артык булган, комплекттан тыш булган; *сверхкомплектное имущество* — комплекттан тыш булган милек.

**СВЕРХМАГИСТРА'ЛЬ** *ж. ж.-д.* — зур магистраль (махсус җиһазландырылган көчле зур магистраль).

**СВЕРХМЕ'РНЫЙ** — чиктән тыш зур үлчәүле.

**СВЕРХМЕ'ТКИЙ** — чиктән тыш туры ата торган.

**СВЕРХМО'ЩНЫЙ** *тех.* — гадәттән тыш көчле; чиктән тыш көчле; *сверхмощный двигатель* — чиктән тыш көчле двигатель.

**СВЕРХПРИ'БЫЛЬ** *ж.* — өстәмә табыш, өстәмә файда (капиталистик җәмгыятьтә уртача табыштан югары табыш).

**СВЕРХРА'ННИЙ** — гадәттән тыш иртә; *сверхранний сев* — гадәттән тыш иртә чәчү.

**СВЕРХСКОРОСТНО'Й** — зур тизлекле, гадәттән тыш тизлекле, гадәттән тыш тиз...-а торган; *сверхскоростная авиация* — зур тизлекле авиация.

**СВЕРХСМЕ'ННЫЙ** *спец.* — сменадан тыш, сменадан тыш...-а торган; *сверхсменная работа* — сменадан тыш эшләнә торган эш.

**СВЕРХСМЕ'ТНЫЙ** *экон. бухг.* — сметадан тыш булган; *сверхсметные расходы* — сметадан тыш булган расходлар.

**СВЕРХСРО'ЧНИК** *м. воен.* — сверхсрочник (срогы тулганнан соң үз теләге белән хәрби хезмәттә калучы).

**СВЕРХСРОЧНОСЛУ'ЖАЩИЙ** — к. сверхсрочник.

**СВЕРХСРО'ЧНЫЙ** — 1. сроктан тыш, билгеләнгән вакыттан тыш; *сверхсрочная служба в армии* — армиядә сроктан тыш хезмәт итү; 2. (*крайне срочный*) бик ашыгыч, артык ашыгыч.

**СВЕ'РХУ** — 1. *нареч.* өстә; *сало плавает сверху* — май өстә йөзә; 2. *нареч.* өстән; *масло испортилось сверху* — май өстән бозылган; 3. *нареч.* югарыдан, өстән; *вода падает сверху* — су югарыдан төшә; *смотреть сверху вниз* — өстән аска карау; 4. *нареч. книж.* югарыдан, өстән (житәкче органнар тарафыннан бирелгән); *директива сверху* — югарыдан бирелгән директива; 5. *предлог с род. п. простореч.* өстеннән; *сверху дерева* — агач өстеннән. ◇ **Сверху донизу** — 1) астан өскә кадәр, астан өскә хәтле; *провести линию сверху донизу* — астан өскә хәтле сызык үткәрү; 2) *перен.* үтәдән-үтә, үтәдән-үтәгә; *дождь промочил его сверху донизу* — аны яңгыр үтәдән-үтә чылаткан; 3) югарыдан түбәнгә кадәр; *установить демократический централизм сверху д низу* — югарыдан түбәнгә кадәр демократик централизм урнаштыру.

**СВЕРХУРО'ЧНЫЕ** *мн. в знач. сущ.* — эш сәгатеннән тыш эшләп алган акча, сверхурочный акча.

**СВЕРХУРО'ЧНЫЙ** — эш сәгатеннән тыш эшләнгән.

**СВЕРХЧЕЛОВЕ'ЧЕСКИЙ** — кеше көче житмәслек, кеше кулыннан килмәслек; бик кыен, бик авыр; *сверхчеловеческий труд* — кеше көче житмәслек хезмәт.

**СВЕРХЧУ'ВСТВЕННЫЙ** *филос.* — сиземнән тыш булган, танып-белүдән тыш булган (идеалистик философиядә).

**СВЕРХШТА'ТНЫЙ** *офиц.* — штаттан тыш (булган).

**СВЕРХЪЕСТЕ'СТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. табигатьтән өстенлек (дини мистик карашта); 2. могҗизалык, табигый булмаганлык, искиткеч нәрсә, аңлый алмаслык нәрсә.

**СВЕРХЪЕСТЕ'СТВЕННЫЙ** — 1. *книж.* табигатьтән өстен...; *сверхъестественные силы* — табигатьтән өстен көчләр; 2. гадәттән тыш зур; искиткеч; *сверхъестественная скорость* — гадәттән тыш зур тизлек.

**СВЕРЧА'ТЬ** *несов. обл.* — черкелдәү; *сверчок сверчит* — чикерткә черкелди.

**СВЕРЧО'К** *м.* — өй чикерткәсе, шөрчек. ◇ **Всяк сверчок знай свой шесток** — һәркем үз урынын белергә тиеш.

**СВЕРША'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. свершить I.

**СВЕРША'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.* — 1. к. свершиться; 2. *страд.* тәмамлану, тәмам ителү.

**СВЕРШИ'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.* — тормышка ашыручы, башкаручы, үтәүче.

**СВЕРШИ'ТЬ** I *сов. устар.* — к. совершить I в 3 знач.

**СВЕРШИ'ТЬ** II *сов. обл.* — очлау; *свершить стог* — кибәнне очлау.

**СВЕРШИ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар.* — к. совершиться.

**СВЕ'РЩИК** *м.*, **СВЕ'РЩИЦА** *ж. спец.* — чагыштыручы, чагыштырып төзәтүче.

**СВЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. сверить.

**СВЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *простореч. обл.* к. свериться; 2. *страд.* чагыштырылу, чагыштырып каралу, чагыштырып укылу.

**СВЕ'СИТЬ** *сов.* — 1. салындыру, асылындыру, салындырып кую; *свесить ноги* — аякларны салындыру; 2. *спец.* салындырып төшереп...-у; *свесить кровлю* — өй түбәсенең читләрен салындырып төшереп ябу; 3. *разг.* к. свешать.

**СВЕ'СИТЬСЯ** *сов.* — 1. салыну, салынып төшү, салынып тору; 2. (берәр нәрсә аркылы) иелеп түбән карау; *свеситься через перила* — култыкса аркылы иелеп түбән карау; 3. *разг.* к. взвеситься.

**СВЕСТИ'** *сов.* — 1. житәкләп төшерү, житәкләп алып төшү; *свести слепого с лестницы* — сукыр кешене баскычтан житәкләп алып төшү; 2. төшерү; *свести вопрос с принципиальной высоты* — мәсьәләне принципиаль югарылыктан төшерү; 3. алып китү; *свести лошадь с лужка* — атны болыннан алып китү; 4. *обл.* урлап чыгу, урлап алып китү, алып китү; *корову свели со двора* — сыерны йорттан урлап алып киткәннәр; 5. икенче урынга күчерү; 6. *разг.* илтү, илтеп кую; *Машу да Гришу свели ночевать к соседке* — Маша белән Гришаны күрше хатынга кунарга илтеп куйдылар; 7. алып барып кайту, алып барып килү; *свести детей в кино* — балаларны киногa алып барып кайту; 8. *простореч.* жыю; *свёл всех ребят в зал* — балаларның барысын да залга жыйган; 9. очраштыру; *судьба свела* — язмыш очраштырды; 10. якынлаштыру, тоташтыру; *свести ветви дерева* — агачның ботакларын тоташтыру; 11. кушу, бергә кушу; *свести партизанские отряды* — партизан отрядларын бергә кушу; 12. чагыштырып йомгак ясау (йомгак чыгару); *свести показания различных источников* — төрле чыганакларның күрсәткечләрен чагыштырып йомгак ясау; 13. калдыру; *свести расходы к минимуму* — расходларны минимумга калдыру; 14. әйләндерү, кайтарып калдыру; *свести все дело к пустякам* — бөтен эшне юк-барга әйләндерү; *он свёл все дело к своей болезни* — ул бөтен эшне үзенең авыру булуына кайтарып калдырды; 15. бору; *свести разговор на вчерашний случай* — сүзне кичәге вакыйгага бору; 16. күчереп төшерү; *свести рисунок на кальку* — рәсемне калькага күчереп төшерү; 17. *обл. спец.* кисеп бетерү, юкка чыгару; *свести небольшую березовую рощу* — кечкенә каенлыкны кисеп бетерү; 18. бетерү; *свести пятно* — тапны бетерү. ◇ **Свести дружбу** — дуслашу. **Свести крышу** — (өйнең) түбәсен ябып бетерү. **Свести на нет** — юкка чыгару. **Мне ногу свело** — аягымны көзән жыерды. **Не сведя конца** *устар.* — очына чыкмыйча, очына чыгалмыйча, бетермичә, эшен бетермичә. **Свести (сводить) концы с концами** — к. конец. **Свести счёты** — исәпләшү; үч алу, үч кайтару. **Свести с ума** — акылдан яздыру.

**СВЕСТИ'СЬ** *сов.* — 1. күчерелү, күчереп алыну; *картинка свелась плохо* — картинка начар күчерелгән; 2. кайтып калу; *всё свелось к пустякам* — эш юк-бар нәрсәгә кайтып калды.

**СВЕТ I** *м.* — 1. яктылык, якты; *лунный свет* — ай яктысы; *свет лампы* — лампа яктысы; 2. ут; *свет погас* — ут сүнде; 3. яктыру, таң ату; *встать до свету* — таң атканчы тору; 4. *обл.* күрү; *у него свет отнялся* — ул күрми башлаган; 5. дөнья яктылыгы, дөнья яктысы; *жили в нужде, только теперь увидели свет* — фәкыйрь тордык, хәзер генә дөнья яктысын күрдек. ◇ **Чуть свет** — таң ярылгач та, таң тишегеннән. **Свет жизни моей** — күз нурым. **Зал в два света** — тәрәзәләре аслы-өсле ике рәт итеп урнаштырылган зал. **В свете новых данных** — яңа мәгълүматлар күзлегеннән (караганда). **Всё видеть в тёмном свете** — һәрнәрсәнең начар ягын гына күрү. **Будущность представляется мне в самом розовом свете** — киләчәк миңа бик алсу төстә күренә. **Посмотреть на свет** — утка тотып карау. **На свету** — ут яктысында. **Не взвидеть света** — к. взвидеть. **Ни свет ни заря** — таң тишегеннән. **Пролить свет** или **бросить свет** — ачыклау. **Свет очей моих** — күз нурым.

**СВЕТ II** *м. мн.* нет — 1. *(мир)* дөнья, жир йөзе, жиһан; 2. *устар.* (буржуаз-дворяннар телендә) өстен катлау, югары жәмгыять; 3. *(окружающая среда)* мохит. ◇ **Белый свет** — якты дөнья. **Выпустить в свет** — басып чыгару, дөньяга чыгару (китапны). **На чём свет стоит** *разг. фам.* — эттән алып эткә салып; *ругать на чём свет стоит* — эттән алып эткә салып сүгү. **Не ближний свет** *простореч.* — якын түгел. **Новый свет** — к. новый. **Оставить** или **покинуть свет (мир)** — к. оставить. **Отправить на тот свет** *разг.* — үтерү, теге дөньяга жибәрү. **Отправиться на тот свет** *разг.* — үлү, теге дөньяга китү. **Произвести на свет** *книж. устар.* — тудыру, дөньяга китерү. **Свет не клином сошёлся** — дөнья киң. **Света преставленье** — к. светопреставление. **Согнать** или **сжить со свету** *разг.* — һәлак итү, гүргә кертү. **Старый свет** — к. старый. **Явиться на свет** или **увидеть свет** — 1. дөньяга килү, туу, барлыкка килү; 2. *перен.* дөньяга чыгу, дөнья йөзен күрү, басылып чыгу.

**СВЕТА'ТЬ** *несов.* — яктыру, таң ату.

**СВЕТЁЛКА** *ж. устар.* — (өске каттагы) кечкенә чиста бүлмә, чарлак.

**СВЕТЕ'Ц** *м. старин.* — чыра аслыгы (борын заманда өйне чыра белән яктыртканда чыра астына куелган аслык).

**СВЕ'ТИК** *м.* — күз нурым, акыллым.

**СВЕТИ'ЛО** *ср. книж.* — 1. *астр.* яктырткыч (кояш, ай һ. б.); 2. *перен.* акыл иясе, атаклы кеше.

**СВЕТИ'ЛЬНИК** *м.* — 1. зур лампа; 2. *перен.* акыл иясе, (берәр фән) атаклысы.

**СВЕТИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — яктырткыч..., як-

тырта торган; *светильный газ* — яктырта торган газ.

**СВЕТИ'ЛЬНЯ** *ж.*— филтә.

**СВЕТИ'ТЬ** *несов.*— 1. яктырту, яктылык бирү; 2. яктыртып тору (мәсәлән, берәр кеше карангыда берәр нәрсә эзләгәндә).

**СВЕТИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. күренү, тоныкланып ялтырау; *тускло светится луна* — тонык кына булып ай күренә; *в окнах светились огни* — тәрәзәләрдә утлар күренә иде; 2. ялтырау, ялтырап күренү; *в его усах светились седые волосы* — аның мыекларында ак бөртекләр ялтырый иде; 3. *перен.* балку, балкып тору; *в глазах его светилась радость* — аның күзләрендә шатлык балкый иде.

**СВЕТЛЕ'ТЬ** *несов.*— 1. яктыру; *на улице светлеет* — тышта яктыра; 2. *перен.* ачылу, ачыклану, ачыла бару; *взгляд светлеет* — йөзе ачыклана, чырае ачыла; *ум светлеет* — акыл ачыла бара; 3. *(виднеться—о чем-н. светлом)* яктырып күренеп тору.

**СВЕТЛЕ'ТЬСЯ** *несов.*— ялтырап күренү; ялтырау.

**СВЕТЛИНА'** *ж. мн.* нет, *обл.*— якты тап, якты урын, якты тимгел.

**СВЕТЛИ'ЦА** *ж. устар. обл.*— ак өй, өй түре.

**СВЕТЛО'** *нареч.*— 1. якты; *лампа светло горит* — лампа якты яна; 2. *в знач. сказ.* якты; *здесь светло* — монда якты; 3. *перен.* шат, күтәренке (күңел, рух турында).

**СВЕТЛОВА'ТЬ** *несов. спец.*— ялтырату; ялтыравык йөгертү.

**СВЕТЛОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— ялтыратылу, ялтыравык йөгертелү.

**СВЕ'ТЛОСТЬ** *ж. устар.*— яктылык. ◇ **Ваша светлость** *доревол.*— галиҗәнап (электә югары дәрәҗәле князьләргә мөрәҗәгать иткәндә кулланылган).

**СВЕ'ТЛЫЙ** — 1. якты; *светлое солнышко* — якты кояш; 2. ялтырый торган, ялтыравыклы; *светлые пуговицы* — ялтыравыклы төймәләр; 3. тонык; *светлая вода* — тонык су; 4. *книжн.* шатлыклы, күңелле. ◇ **Светлый ум** — саф акыл.

**СВЕТЛЫ'НЬ** *ж. мн.* нет, *простореч.*— якты, яктылык (ай һәм йолдызлар яктысы турында әйтелә).

**СВЕТЛЯ'К, СВЕТЛЯЧО'К** *м.*— тычкан уты (бөҗәк).

**СВЕТОБОЯ'ЗНЬ** *ж. мн.* нет, *мед.*— яктыдан курку (күзнең яктыга чыдамау авыруы).

**СВЕТОВО'Й** — 1. яктылык...-ы; *световой луч* — яктылык нуры; *световые волны* — яктылык дулкыннары; 2. яктылык ярдәмендә...-ган; *световая сигнализация* — яктылык ярдәмендә бирелә торган сигналлар.

**СВЕТОЗА'РНЫЙ** *поэт. ритор.*— нурлы, нур чәчеп торган.

**СВЕТОЛЕЧЕ'БНИЦА** *ж. мед.*— яктылык белән дәвалау больницасы.

**СВЕТОЛЕЧЕ'БНЫЙ** — яктылык белән дәвалау...-ы; *светолечебный кабинет* — яктылык белән дәвалау кабинеты.

**СВЕТОЛЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.*— яктылык белән дәвалау.

**СВЕТОЛЮ'Б** *м. бот.*— яктылык сөюче, яктылык яратучы (үсемлек).

**СВЕТОЛЮБИ'ВЫЙ** — яктылык яратучан, яктылык сөючән.

**СВЕТОМАСКИРО'ВКА** *ж. мн.* нет — яктылыкны маскировкалау, ут яктысын маскировкалау.

**СВЕТОМАСКИРО'ВОЧНЫЙ** — яктылыкны маскировкалау...-ы; *светомаскировочный материал* — яктылыкны маскировкалау материалы.

**СВЕТОМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет — светометрия (аткан снаряд ялтыравына карап дошман батареяларының урнашкан җирен билгеләү).

**СВЕТОНО'СНЫЙ** — якты, яктылык чәчә торган, яктылык бирә торган; *светоносный луч* — яктылык чәчә торган нур.

**СВЕТОПИ'СНЫЙ** *устар.*— фотографик; *светописный рисунок* — фотографик рәсем.

**СВЕ'ТОПИСЬ** *ж. мн.* нет, *устар.*— фотография.

**СВЕТОПРЕСТАВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *церк.*— 1. кыямәт көне; 2. *перен.* тәртипсезлек, чуалчыклык, буталчыклык; 3. *разг. шутл.* *(тьма)* карангылык.

**СВЕТОРАССЕ'ЯНИЕ** *ср. мн.* нет, *физ.*— яктылык чәчелү (төрле төстәге яктылык нурларының яктылыкны сындыра торган мохит аша үткәндә төрле якка чәчелүе).

**СВЕТОСИ'ЛА** *ж.*— яктылык көче, нур көче.

**СВЕТОСТО'ЙКИЙ** — уңмый торган, төсе китми торган (буяулар турында).

**СВЕТОСТО'ЙКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *хим.*— уңмаучылык, төсе китмәүчәнлек, төсе бетмәүчәнлек.

**СВЕТОТЕ'НЬ** *ж. живоп.*— күләгә, яктылык күләгәсе.

**СВЕТОТЕ'ХНИКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— яктылык техникасы (техниканың яктылыкны алу һәм куллану юлларын өйрәнә торган бүлеге).

**СВЕТОФИ'ЛЬТР** *м. физ. спец.*— яктылык фильтры, яктылык сөзгеч.

**СВЕТОФО'Р** *м.*— светофор (урамдагы, юллардагы хәрәкәтне тәртипкә салу өчен кызыл, сары, яшел төстәге яктылык бирә торган сигнал фонаре).

**СВЕ'ТОЧ** *м.*— 1. *устар.* зур шәм, факел; 2. *перен.* чыганак, кояш (белем чыганагы, хакыйкать чыганагы, ирек чыганагы, яктылык чыганагы); *Советский Союз — светоч прогресса* — Советлар Союзы — прогресс чыганагы.

**СВЕТОЧУВСТВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — яктылыкка сизгер, яктылыкны сизә торган; *светочувствительная бумага* — яктылыкны сизә торган кәгазь.

**СВЕ'ТСКИЙ** — 1. *устар. доревол.* аристократлар...-ы; аристократларга (югары сыйныфларга) хас булган; *светская жизнь* — аристократларга хас тормыш; 2. *устар. доревол.* әдәпле, тәрбияле (буржуаз-дворяннар телендә); 3. дөньяви (дини булма-

ган); *светское образование* — дөньяви белем.

**СВЕЧА'** *ж.* — 1. шәм; 2. *тех.* свеча (эчке янулы двигательләрдә электр чаткысы чыгарып кабындыра торган җайланма); 3. шәм (яктылык көчен үлчәү берәмлеге); *лампочка в 50 свечей* — 50 шәмле лампочка. ◇ **Игра не стоит свеч** — к. игра.

**СВЕЧЕ'НИЕ** *ср.* — яктылык бирү, яктылык нуры чәчү.

**СВЕЧЕРЕ'ТЬ** *сов. поэт. устар.* — кич булу, караңгы төшү.

**СВЕ'ЧКА** *ж.* — 1. к. свеча; 2. *мед.* свечка.

**СВЕЧНИ'К** *м. спец.* — 1. шәм сатучы; 2. шәм ясаучы.

**СВЕЧНО'Й** — шәм...-ы; *свечной завод* — шәм заводы.

**СВЕ'ШАТЬ** *сов. разг.* — үлчәү; *свешать кило ягод* — бер кило җиләк үлчәү.

**СВЕ'ШАТЬСЯ** *сов. просторечн.* — үлчәнү.

**СВЕ'ШИВАТЬ** *несов.* — к. свесить.

**СВЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. свеситься; 2. *страд.* салындырып төшерелү, салындырып куелу.

**СВЕ'ЯТЬ** *сов. книж.* — өреп (очырып) төшерү; *ветром свеяло бумаги со стола* — өстәлдән кәгазьләрне җил өреп төшергән.

**СВИВА'ЛЬНИК** *м.* — биләүсә; *детский свивальник* — бала биләүсәсе.

**СВИВА'ЛЬНЫЙ** — биләү...-ы; *свивальная тесьма* — биләү тасмасы.

**СВИВА'ТЬ** *несов.* — 1. к. свить; 2. *(младенца)* биләү.

**СВИДА'НИЕ** *ср.* — күрешү, очрашу. ◇ **До свидания** — исән бул, исән булыгыз, сау бул, сау булыгыз, хушыгыз.

**СВИДЕ'ТЕЛЬ** *м.* — шаһит, танык, гуаһ, үз күзе белән күрүче, күрүче. ◇ **Благородный свидетель** *разг. ирон.* — читтән карап торучы (эшкә катнашмаучы).

**СВИДЕ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — к. свидетель.

**СВИДЕ'ТЕЛЬСКАЯ** *ж. в знач. сущ.* — (судта) шаһитлар бүлмәсе.

**СВИДЕ'ТЕЛЬСКИЙ** — шаһит...-ы; *свидетельские показания* — шаһит күрсәтүләре.

**СВИДЕ'ТЕЛЬСТВО** *ср. книж.* — 1. *(показание)* күрсәтү; 2. дәлил, күрсәткеч, раслаучы факт; 3. *офиц.* (*документ*) таныклык.

**СВИДЕ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов.* — 1. *офиц.* раслау, дөреслеген әйтү; *свидетельствую это перед всеми* — моны мин барлык кешеләр алдында раслыйм; 2. күрсәтү, күрсәтеп тору, раслау; *победа Советской Армии свидетельствует о мощи Советской страны* — Совет Армиясенең җиңүе Советлар иленең куәтен күрсәтә; 3. *офиц.* раслау; *свидетельствовать подпись* — имзаны раслау; 4. *офиц.* карау, тикшерү; *свидетельствовать больных* — авыруларны карау. ◇ **Свидетельствовать почтение** *устар.* — ихтирам белдерү, хөрмәт күрсәтү.

**СВИДЕ'ТЕЛЬСТВОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — раслану, исбат ителү.

**СВИ'ДЕТЬСЯ** *сов. разг.* — күрешү, очрашу.

**СВИЛЕВА'ТЫЙ** — кыек катламлы (үзагач турында).

**СВИ'ЛИВАТЬ** *несов. просторечн.* — к. свильнуть.

**СВИЛОВА'ТЫЙ** *обл.* — к. свилеватый.

**СВИЛЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — 1. кыек катламлылык (үзагач җепселләренең бормалы-сырмалы булуы); 2. (пыяла эчендәге) дулкынлы (тигезсез) катлам.

**СВИЛЬНУ'ТЬ** *сов. просторечн.* — тайпылу, читкә тайпылу.

**СВИНА'РКА** *ж.* — дуңгыз карачы.

**СВИНА'РНИК** *м. с.-х.* — дуңгыз абзары.

**СВИНА'РНЫЙ** — дуңгыз үрчетү...-ы; *свинарное хозяйство* — дуңгыз үрчетү хуҗалыгы.

**СВИНА'РНЯ** *ж. с.-х.* — к. свинарник.

**СВИНА'РЬ** *м. с.-х.* — дуңгыз караучы.

**СВИНЕ'Ц** *м. мн.* нет — 1. кургаш, кургашын, кара кургаш; *пломба из свинца* — кургаш пломба; 2. *перен.* пуля; *разведчиков встретили свинцом* — разведчикларны пуля белән каршы алдылар. ◇ **Подернуться свинцом** *поэт.* — кара-күгелҗем төскә керү; *вода подернулась свинцом* — су кара-күгелҗем төскә кергән. **Свинцом лечь на сердце** — йөрәккә таш булып яту.

**СВИНИ'НА** *ж. мн.* нет — дуңгыз ите.

**СВИ'НКА** *ж.* — 1. кечкенә дуңгыз, яшь дуңгыз; 2. *мед.* колак арты бизе шешү; 3. *тех. (слиток металла)* металл кисәге; 4. *обл.* чүрәкә (бура кебек уеннарда). ◇ **Морская свинка** *зоол.* — диңгез дуңгызы.

**СВИНОБО'ЕЦ** *м. спец. обл.* — дуңгыз суючы (эшче).

**СВИНОВО'Д** *м.* — дуңгыз үрчетү белгече.

**СВИНОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — дуңгыз үрчетү, дуңгыз асраучылык.

**СВИНОВО'ДЧЕСКИЙ** — дуңгыз асраучылык...-ы; *свиноводческий район* — дуңгыз асраучылык районы.

**СВИНО'Й** — 1. дуңгыз...-ы; *свиное сало* — дуңгыз мае; 2. дуңгыз итеннән...-ган; *свиные котлеты* — дуңгыз итеннән пешерелгән котлет; 3. дуңгыз тиресеннән ясалган; *свиная кожа* — дуңгыз тиресеннән ясалган күн.

**СВИНОМА'ТКА** *ж. с.-х.* — ана дуңгыз.

**СВИНОПА'С** *м.* — дуңгыз көтүчесе.

**СВИНОСОВХО'З** *м. с.-х.* — дуңгыз үрчетү совхозы.

**СВИНОФЕ'РМА** *ж. с.-х.* — дуңгыз фермасы.

**СВИ'НСКИЙ** *разг.* — 1. пычрак, шакшы; 2. әшәке, кабахәт; *свинский поступок* — әшәке эш.

**СВИ'НСТВО** *ср. разг. неодобр.* — 1. *(подлость)* әшәкелек, кабахәтлек; дуңгызлык; 2. пычрак, пычрак урын, шакшы урын; *нельзя жить в таком свинстве* — мондый пычракта торырга мөмкин түгел.

**СВИНТИ'ТЬ** *сов.* — 1. винт белән беркетү, винтлап беркетү; 2. борып алу, борып чыгару; *свинтить гайку* — гайканы борып алу; 3. *(испортить, много винтя)* бора-бора бозу, күп борып бозып бетерү.

**СВИНТИ'ТЬСЯ** *сов. просторечн.* — күп борылып сыры бетү, күп борылып бозылу; *гайка свинтилась* — гайка күп борылып бозылган.

**СВИ'НТУС** *м. разг. фам.* — дуңгыз малай, дуңгыз; *ах, ты свинтус* — әх, син, дуңгыз.
**СВИНУ'ХА** *ж. обл.* — к. сыроежка.
**СВИНУ'ШНИК** *м.* — к. свинюшник.
**СВИНЦЕВА'ТЬ** *несов. тех.* — кургашлау, кургаш йөгертү.
**СВИНЦЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — кургашлану, кургаш йөгертелү.
**СВИНЦО'ВЫЙ** — 1. кара кургаш...-ы; *свинцовая руда* — кара кургаш рудасы; 2. кара кургаштан ясалган, кургаш; *свинцовая пуля* — кара кургаштан ясалган пуля; 3. кургашлы; *свинцовые соли* — кургашлы тозлар; 4. *перен.* кара, кара-кучкыл; *свинцовые тучи* — кара-кучкыл болытлар. ◇ **Свинцовая тяжесть на сердце** — йөрәктә таш яту.
**СВИНЧА'К** *м. мн.* нет, *мин.* — кургаш рудасы.
**СВИНЧА'ТКА** *ж.* — 1. *простореч.* кургашлы кузна, эретеп кургаш салынган кузна; 2. *спец.* кургаш батыргычлы ятьмә; 3. *разг.* очы кургашлы камчы.
**СВИ'НЧИВАТЬ** *несов.* — к. свинтить.
**СВИ'НЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *простореч.* к. свинтиться; 2. *страд.* винтлап куелу, винтлап беркетелү; 3. *страд.* борып чыгарылу.
**СВИНЬЯ'** *ж.* — 1. дуңгыз; 2. *перен. разг. презрит.* дуңгыз, шакшы кеше, кабахәт кеше. ◇ **Подложить свинью** — кабахәтлек эшләү, аяк чалу. **Свинья-свиньёй** — дуңгызның да дуңгызы, нәкъ дуңгыз.
**СВИНЮ'ШНИК** *м. обл.*, **СВИНЯ'РНИК** *м. обл.*, **СВИНЯ'РНЯ** *ж. обл.*, **СВИНЯ'ТНИК** *м. обл.* — к. свинарник.
**СВИНЯ'ЧИЙ** *простореч. фам.* — дуңгызга хас.
**СВИНЯ'ЧИТЬ** *несов. разг. фам.* — дуңгыздай кылану, үзеңне дуңгызсыман тоту; пычрату, шакшылау.
**СВИРЕ'ЛЬ** *ж.* — курай, сыбызгы.
**СВИРЕ'ЛЬНЫЙ** — курай...-ы, сыбызгы...-ы; *свирельный звук* — курай тавышы.
**СВИРЕПЕ'ТЬ** *несов.* — кансызлану, ерткычлану, мәрхәмәтсезләнү.
**СВИРЕ'ПОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. рәхимсезлек; *свирепость зимы* — кышның рәхимсезлеге; 2. явызлык, кансызлык; *обнаружить свирепость* — кансызлык күрсәтү.
**СВИРЕ'ПСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.* — к. свирепствовать 2.
**СВИРЕ'ПСТВОВАТЬ** *несов. книж.* — 1. ерткычлану, рәхимсез кылану; 2. котырыну, бик көчле булу; *буря свирепствует* — давыл котырына; 3. *перен.* кыру; *мор свирепствует в лесах* — урманнарда үләт кыра (җәнлекләрне).
**СВИРЕ'ПЫЙ** — 1. ерткыч, кансыз, рәхимсез; 2. *(очень сердитый)* бик усал, бик ачулы; 3. *(о ень сильный)* бик көчле, һәлакәтле.
**СВИРИСТЕ'ЛКА** *ж. обл.* — сыбызгы.
**СВИРИСТЕ'ЛЬ** *м. зоол.* — свиристель (кош).
**СВИРИСТЕ'ТЬ** *несов. обл.* — чирелдәү, чирелдәп сызгыру.
**СВИРО'К** *м. зоол. обл.* — к. турпан.
**СВИСА'ТЬ** *несов.* — салынып тору, салынып төшү.
**СВИ'СЛЫЙ** — салынып төшкән; *свислые усы* — салынып төшкән мыек.
**СВИ'СНУТЬ** I *сов.* — салынып төшү.
**СВИ'СНУТЬ** II — к. свистнуть.
**СВИСТ** *м.* — 1. сызгырган тавыш, сызгыру, сызгыру тавышы; *раздался свист* — сызгырган тавыш ишетелде; 2. чырылдау; *птичий свист* — кошлар чырылдавы; 3. сызгыру, ыжгыру, выжылдау; *свист пуль* — пулялар сызгыру; *свист ветра* — җил ыжгыру.
**СВИСТА'ТЬ** *несов.* — к. свистеть 1, 3, 4. ◇ **Свистать в кулак** *простореч.* — к. свистеть в кулак. **Ищи свищи** *разг. фам.* — җилләр искән.
**СВИСТЕ'ЛКА** *ж. простореч.* — к. свистулька.
**СВИСТЕ'ТЬ** *несов.* — 1. сызгыру; *мальчик свистит* — малай сызгыра; 2. сызгыру; кычкырту; сыбызгы сызгырту; *милиционер свистит* — милиционер сызгырта; *паровоз свистит* — паровоз кычкырта; 3. сызгыру, ыжгыру; *ветер свистит* — җил ыжгыра; 4. сызгырып чакыру, сызгыртып чакыру. ◇ **В кармане свистит** *разг. шутл.* — кесәдә җилләр уйный (ягъни кесәдә акча юк). **Свистеть в кулак** — бер тиен акчасыз йөрү.
**СВИ'СТНУТЬ** *сов.* — 1. сызгырып җибәрү; 2. *простореч.* тондыру, ялтырату; *свистнуть по уху* — колак төбенә ялтырату; 3. *простореч. фам.* чәлдерү, сөртү, сыпырту; *у меня свистнули часы* — минем сәгатьне сөрткәннәр. ◇ **Когда рак свистнет** — кызыл кар яугач.
**СВИСТО'К** *м.* — 1. сыбызгы, свисток; 2. сызгырту; кычкырту; *пароход дал свисток* — пароход кычкыртты.
**СВИСТОПЛЯ'СКА** *ж. мн.* нет, *пренебр.* — котырыну, чиктән тыш йөгәнсезләнү.
**СВИСТУ'ЛЬКА** *ж. разг.* — сыбызгы, уенчык сыбызгы.
**СВИСТУ'Н** *м.* — 1. сызгырырга яратучы; 2. оста сызгыручы; 3. *перен. устар. презрит. (бездельник, прожигатель жизни)* эшлексез, җилкуар, типтереп йөрүче, әрәмтамак.
**СВИСТУ'НЬЯ** *ж.* — к. свистун 1.
**СВИСТУ'ХА** *ж. обл.* — кыр үрдәге(нең бер төре).
**СВИСТЯ'ЩИЙ** — 1. сызгыра торган; 2. *лингв.* сызгырулы; *свистящие звуки* — сызгырулы авазлар.
**СВИ'ТА** I *ж. устар.* — свита (1. югары дәрәҗәдәге кешенең янында йөрүче, озатучы, саклаучы кешеләр; 2. *дореволюц.* патша янында йөрүче офицерлар; 3. *перен. разг. шутл.* иярченнәр, ияреп йөрүчеләр).
**СВИ'ТА** II *ж.* — чоба (Украинада чикмәннең бер төре).
**СВИ'ТЕР** *м.* — свитер (каптырмасыз фуфайка).
**СВИ'ТКА** *ж.* — к. свита II.
**СВИ'ТОК** *м.* — 1. *истор.* төргәк (уклау-

сыман итеп төрелгән кәгазь); 2. *(старинная рукопись)* борынгы кулъязма. ◇ **Свиток воспоминаний** — истәлекләр тезмәсе.

**СВИ'ТЬ** *сов.* — 1. ишү, ишеп кую; *свить верёвку* — бау ишеп кую; 2. үрү, үреп кую; *свить венок* — венок үреп кую; 3. ясау, ясап кую; *свить гнездо* — оя ясап кую; 4. *простореч.* төреп кую, бөтереп кую (кәгазьне, яфракны уклаусыман итеп).

**СВИ'ТЬСЯ** *сов.* — бөгәрләнү, уралу, йомарлану; *змея свилась клубком* — елан йомгак кебек бөгәрләнгән.

**СВИХНУ'ТЬ** *сов.* — каймыктыру; *свихнуть ногу* — аякны каймыктыру. ◇ **Свихнуть с ума** — акылдан язу, шашу. **Свихнуть себе шею** *разг. фам.* — уңышсызлыкка очрау, һәлак булу, муен сындыру.

**СВИХНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. акылдан язу, акылдан шашу; 2. юлдан язу, бозыклыкка бирелү.

**СВИЩ** *м.* — 1. тишек (тиредә укра тишкән тишек, чикләвектә корт тишкән тишек һ. б.); 2. *мед.* эренле тирән яра; 3. *тех.* (металлны койганда хасил булган) куыш, куышлык; 4. *перен. устар. пренебр.* эшлексез кеше, әрәм тамак.

**СВИЯ'ЗЬ** *ж.* — кыр үрдәге(нең бер төре).

**СВОБО'ДА** *ж.* — азатлык, ирек. ◇ **На свободе** — буш вакытта. **Свобода морей** *полит.* — судноларның диңгездә ирекле йөрүе. **Свобода рук** *полит.* — комачаусыз үз политикасын тормышка ашыру мөмкинлеге.

**СВОБО'ДНО** *нареч.* — иркен, иркен рәвештә, иркенләп.

**СВОБО'ДНЫЙ** — 1. азат, хөр, ирекле; *свободный народ* — азат халык; *свободный человек* — ирекле кеше; 2. иркен; *свободное дыхание* — иркен сулыш; 3. иркен, киң; *свободное пальто* — иркен пальто; 4. буш; *свободное место* — буш урын; *свободное время* — буш вакыт; 5. артык, буш яткан, запас; *нет свободных денег* — буш яткан акча юк. ◇ **Свободный художник** *дореворл.* — ирекле художник (1. Художество академиясен кечкенә көмеш медальгә бетергән кеше; 2. югары музыкаль белем алган музыкант). **Свободный удар** *спорт.* — ирекле удар (каршы якның һөҗүм итәргә хокукы булмаганда туп бәрү).

**СВОБОДОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж. ритор.* — ирек сөючән.

**СВОБОДОЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — ирек сөю, ирек сөючәнлек.

**СВОБОДОМЫ'СЛИЕ** *ср. книж.* — хөр фикерлелек.

**СВОБОДОМЫ'СЛЯЩИЙ** *книж.* — хөр фикерле.

**СВОД** *м.* — 1. *только ед. (действие)* к. свести 1, 3, 10, 11, 12, 17, 18; 2. җыелма; *свод законов* — законнар җыелмасы; 3. *арх.* гөмбәз; *каменный свод* — таш гөмбәз.

**СВОДИ'ТЬ** I *сов. разг.* — алып барып кайту; *сводить детей в кино* — балаларны кинога алып барып кайту.

**СВОДИ'ТЬ** II *несов.* — к. свести (7 нче мәгънәдән башкалары). ◇ **Глаз не сводить** — күз алмый карап тору.

**СВОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. кайтып калу; *дело сводится к следующему* — эш менә нәрсәгә кайтып кала; 2. *страд.* якынлаштырылу, тоташтырылу; 3. күчереп төшерелү (рәсем); 4. бетерелү (тап).

**СВО'ДКА** *ж.* — сводка (1. берәр нәрсә турында мәгълүмат, хәбәр язылган документ, записка; 2. *тип.* китапны басар алдыннан алынган оттиск).

**СВО'ДНИК** *м. офиц.* и *презрит.* — димче, арадаш; уйнашка өндәүче, бозыклыкка өндәүче.

**СВО'ДНИЦА** *ж.* — к. сводник.

**СВО'ДНИЧАТЬ** *несов. разг. презрит.* — (зиначылыкта) арадашлык итү.

**СВО'ДНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *офиц. презрит.* — димчелек итү, арадашлык итү (бозыклык эшләүдә).

**СВОДНО'Й** — 1. бергә җыела торган, тоташтырыла торган; 2. күчереп төшерелә торган; *сводная картинка* — күчереп төшерелә торган рәсем.

**СВО'ДНЫЙ** — җыелма; *сводная афиша театров* — театрларның җыелма афишасы; *сводный отряд* — җыелма отряд. ◇ **Сводные братья** — ата бер, ана башка (яки ана бер ата башка) туганнар. **Сводные дети** — ияреп килгән балалар. (икенче тапкыр өйләнешкәндә иренең беренче хатыныннан, хатынның беренче иреннән калган балалар).

**СВО'ДНЯ** *ж разг. презрит.* — к. сводница.

**СВО'ДЧАТЫЙ** — гөмбәзле, көймәле; *сводчатый потолок* — гөмбәзле түшәм.

**СВО'ДЧИК** *м.* — 1. төзәтмәләр кертүче наборщик; 2. *устар.* к. маклер.

**СВОЕВЛА'СТИЕ** *ср. мн.* нет — үз властьлылык, үзе теләгәнчә идарә итү.

**СВОЕВЛА'СТНЫЙ** *книж. устар.* — үз сүзле, үзе теләгәнчә эш итә торган.

**СВОЕВО'ЛИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — үз-иреклелек, башбаштаклык.

**СВОЕВО'ЛЬНИК** *м.*, **СВОЕВО'ЛЬНИЦА** *ж. разг.* — башбаштак кеше.

**СВОЕВО'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. разг.* — башбаштаклык итү, үзе теләгәнчә эш итү.

**СВОЕВРЕ'МЕННОСТЬ** *ж. книж.* — үз вакытында булу, вакытлы булу.

**СВОЕВРЕ'МЕННЫЙ** — 1. үз вакытында...-ган, вакытлы...-ган, бик вакытлы...-ган; *своевременная помощь* — үз вакытында күрсәтелгән ярдәм; 2. билгеләгән вакытта..., вакытында...; *своевременный приход на работу* — эшкә вакытында килү.

**СВОЕКОРЫ'СТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — хирыслык, үз интересларын гына күзәтү, үз җаен гына карау.

**СВОЕКОРЫ'СТНЫЙ** — хирыс, үз җаен гына карый торган, үз интересларын гына күзәтә торган.

**СВОЕКО'ШТНЫЙ** *офиц. устар.* — үз акчасына туенучы (ягъни хөкүмәттән стипендия алмыйча); *своекоштный ученик* — үз акчасына туенучы шәкерт.

**СВОЕНРА'ВИЕ** *ср. мн.* нет — үз сүзлелек, кирелек.

**СВОЕНРА'ВНЫЙ** — үз сүзле, кире.

**СВОЕОБРА'ЗИЕ** *ср. мн.* нет — үзенчәлеклелек, үзенә бертөрлелек.

**СВОЕОБРА'ЗНЫЙ** — үзенә бертөрле, үзенчәлекле, үзенә башка, башка бер төрле.

**СВОЕОБЫ'ЧНЫЙ** *устар.* — 1. к. своенравный; 2. к. своеобразный.

**СВОЕРУ'ЧНЫЙ** *канц. устар.* — к. собственноручный.

**СВОЗИ'ТЬ** I *сов. разг.* — (утыртып) алып барып кайту; *свозить ребёнка за город* — баланы шәһәр читенә алып барып кайту.

**СВОЗИ'ТЬ** II *несов.* — к. свезти 1, 3, 4, 5, 6.

**СВОЗИ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. свезтись.

**СВОЙ, СВОЯ', СВОЁ** — 1. *местоим. притяжат.* үз; *жить своими трудами* — үз көче белән көн күрү; *высказать свои соображения* — үз фикерләреңне әйтү; 2. үзенең, үз; *на каждый вопрос свой ответ* — һәрбер сорауга үзенең җавабы; *всему своё место* — һәрнәрсәнең үз урыны бар; 3. *книж.* үз...-ы, үзенә хас; *у всякого свой вкус* — һәркемнең үз зәвыгы бар; 4. *книж.* үзебезнең, үзебезгә якын, якын; *он свой человек* — ул үзебезнең кеше. ◇ **Добиться своего** — үз теләгенә ирешү. **Он опять за своё** — ул тагын үзенекен сөйли. **В своё время** — к. время. **В своём роде** — к. род. **Знать своё место** — к. место. **Идти своей дорогой** — к. дорога. **Называть вещи своими именами** — әйберләрне үз исеме белән атау (турыдан-туры әйтү, тартынмыйча әйтү, хакыйкатьне яшермичә әйтү). **На своих двоих** — к. двое. **Начать своё** — к. начать. **Не в своём уме (быть)** *разг.* — акылдан язган (кешедәй фикер йөртү). **Не своим голосом** (кричать, вопить) *разг.* — ачы тавыш белән (кычкыру һ. б.). **По-своему** — 1. үзе белгәнчә, теләгәнчә; *сделать по-своему* — үзе теләгәнчә эшләү; 2. үзенчә; *всякий по-своему рассуждает* — һәркем үзенчә фикер йөртә, һәркем үзенчә уйлый. **Своих не узнаешь** — арт сабагыңны укытырмын, кирәгеңне бирермен, кая керер тишек таба алмассың. **Свой брат** — үзебезнең кеше. **Своя рука — владыка** — кемнең кулында — шуның авызында.

**СВО'ЙСКИ** *нареч.* — к. по-свойски.

**СВО'ЙСКИЙ** *разг. устар.* — үз...; *это ваше свойское дело* — ул сезнең үз эшегез.

**СВО'ЙСТВЕННИК** *м.* — кода (ир яки хатын ягыннан булган кардәш).

**СВО'ЙСТВЕННИЦА** *ж.* — кодагый, кодача.

**СВО'ЙСТВЕННЫЙ** — хас, хас булган; *он ответил со свойственной ему решительностью* — ул үзенә хас булган катгыйлык белән җавап бирде.

**СВО'ЙСТВО** *ср. книж.* — үзлек, хосусият, сыйфат; *у магнита есть свойство притягивать железо* — магнитның тимерне үзенә тарту хосусияте бар.

**СВОЙСТВО'** *ср. мн.* нет — кода-кодачалык; туган-тумачалык; *быть в свойстве с кем-н.* — берәр кеше белән туган-тумача булу.

**СВОЛА'КИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. сволочь.

**СВОЛА'КИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. сволочься; 2. *страд.* сөйрәп илтеп ташлану.

**СВОЛОЧИ'ТЬ** I *сов. простореч. обл.* — к. сволочь.

**СВОЛОЧИ'ТЬ** II *несов. простореч. вульг.* — сүгү, кабахәт сүзләр әйтеп сүгү.

**СВОЛОЧНО'Й** *простореч. вульг. бран.* — кабахәт, әшәке, түбән, бозык.

**СВО'ЛОЧЬ** *ж.* — 1. *простореч. презрит. устар. (мелкота)* вак-төяк; 2. *собир. разг. бран презрит. (негодные люди)* кабахәтләр; 3. *простореч. бран.* кабахәт, адәм актыгы, сволочь.

**СВОЛО'ЧЬ** *сов. простореч.* — 1. өстерәп төшерү, тартып төшерү; 2. сөйрәп илтеп ташлау, сөйрәп илтеп кую; 3. *фам.* озату, илтеп тапшыру, өстерәп алып бару; *в участок могут сволочь* — участокка өстерәп алып барулары мөмкин; 4. ташып кую; *сволочь мешки в кучу* — капчыкларны ташып өеп кую; 5. *фам. (украсть)* урлау, урлап киту.

**СВОЛО'ЧЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. (көчхәл белән) төшү; *больной через силу с постели сволокся* — авыру көч-хәл белән урыныннан төште; 2. *вульг.* җыелу; *нищие сволоклись на кладбище* — хәерчеләр зиратка җыелганнар.

**СВО'РА** *ж.* — 1. *охот.* эт бавы, бәй, эт чылбыры; *спустить со своры* — бәйдән ычкындыру; 2. *охот.* бер баудагы ике эт; 3. *собир. охот.* (бер хуҗаның) бурзай этләре, эт өере; 4. *перен. разг. пренебр.* ирченнәр; 5. *перен. презрит.* өер, компания, шайка; *свора буржуазных националистов* — буржуаз милләтчеләр өере.

**СВОРА'ЧИВАТЬ** *несов.* — 1. к. своротить; 2. *разг.* к. свертывать.

**СВОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. своротиться.

**СВО'РИТЬ** *несов. охот.* — этләрне бәйләп кую, этне бәйләп кую.

**СВО'РНЫЙ** — баудагы, бәйдәге, бәйләп куелган (эт турында).

**СВОРОВА'ТЬ** *сов. разг.* — урлап чыгу.

**СВОРОТИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* урыныннан кузгату; *своротить камень* — ташны урыныннан кузгату; 2. *простореч.* читкә бору; *своротить лошадь* — атны читкә бору; 3. *простореч.* алып ташлау; *своротить мешок с воза* — капчыкны йөктән алып ташлау; 4. *простореч. вульг.* сындыру, җимерү, имгәтү; *я тебе скулы сворочу!* — мин синең яңагыңны җимерермен! 5. *простореч.* бору; *как ни хитрил, а на то же своротил* — ничек кенә хәйләләмәсен, тагын шуна борды. ◇ **Своротить с ума** — акылдан язу.

**СВОРОТИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — аву; *санки своротились* — чана ауды.

**СВОЯ'К** *м.* — бажа, баҗай.

**СВОЯ'ЧЕНИЦА** *ж.* — *(младшая)* балдыз; *(старшая)* кайнигәч.

**СВЫКА'ТЬСЯ** *несов.* — к. свыкнуться.

**СВЫСОКА'** *нареч.* — эреләнеп, һавала-

нып, үзен-үзе бик югары куеп; *смотреть свысока* — үзен-үзе бик югары куеп карау.

**СВЫ'ЧАЙ**: **свычаи и обычаи** *разг.* — гореф-гадәтләр.

**СВЫ'ЧКА** *ж. обл.* — к. свычай.

**СВЫ'ШЕ** *книж.* —1. *нареч. устар. ирон.* югарыдан, югары идарәләрдән; *по предписанию свыше* — югарыдан алынган боерык буенча; 2. *нареч. церк., поэт. устар.* югарыдан, ходайдан, алладан; 3. *предлог с род. п.* артык, тыш, артыграк; *свыше меры* — үлчәүдән тыш; *на площади собралось свыше тысячи человек* — мәйданга меннән артык кеше җыелган.

**СВЯ'ЗАННОСТЬ** *ж.* — бәйләнгәнлек, чикләнгәнлек, иркен түгеллек; *связанность движений* — хәрәкәтләрнең иркен түгеллеге.

**СВЯ'ЗАННЫЙ** — 1. *книж.* бәйләнгән; *этот вопрос связан с рядом других* — бу мәсьәлә башка бик күп мәсьәләләр белән бәйләнгән; 2. *книж.* чикләнгән, иркен булмаган; *связанные движения* — иркен булмаган хәрәкәтләр; 3. *хим.* кушылган, катнашкан (берәр нәрсә белән); *связанный азот* — катнашкан азот.

**СВЯЗА'ТЬ** *сов.* — 1. бәйләү, бәйләп кую; *связать вещи* — әйберләрне бәйләп кую; 2. *перен.* бәйләү, берләштерү, бергә кушу; *связать рабочее движение с социализмом* — эшчеләр хәрәкәтен социализм белән бәйләү; *судьба связала их* — аларны язмыш бергә кушкан; *связать два понятия* — ике төшенчәне берләштерү; 3. бәйләү, бәйләп ташлау, кулын-аягын бәйләп кую; *связать вора* — каракны бәйләп ташлау; 4. *перен.* буу, кысу, бәйләү; *связать кого-н. обещанием* — берәр кешене вәгъдә белән бәйләү; *связать чью-н. инициативу* — берәр кешенең инициативасын кысу; 5. бәйләү, бәйләп кую, бәйләп бирү; *связать чулок* — оек бәйләү. ◇ **Связать по рукам и ногам** — кул-аягын бәйләү (иркенләп эшләргә мөмкинлек калдырмау).

**СВЯЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* бәйләнү; *два тюка хорошо связались* — ике тюк бергә яхшы бәйләнгән; 2 элемтәгә керү, бәйләнешкә керү, бәйләнеш булдыру; *связаться со штабом по телефону* — телефон аша штаб белән элемтәгә керү; 3. *разг.* (яман юлдаш белән) бәйләнү, бәйләнешкә керү; *связаться с негодяем* — кабахәт кеше белән бәйләнү.

**СВЯЗИ'СТ** *м.*, **СВЯЗИ'СТКА** *ж.* — элемтәче, связист (элемтә эшендә эшләүче).

**СВЯ'ЗКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. связать 1; 2. бәйләм; *связка ключей* — ачкычлар бәйләме, бер бәйләм ачкыч; 3. *разг. редко* бәйләвеч; *слишком тонкая связка, может оборваться* — бик нечкә бәйләвеч, өзелүе мөмкин; 4. *анат.* сеңер, бәйләвеч; *хрящевые связки* — кимерчәк бәйләвечләре; 5. *грам.* хәбәр бәйләгеч (кушма хәбәр составындагы ярдәмче фигыль).

**СВЯЗНО'Й** I — бәйләнеш тоту өчен билгеләнгән; *связная радиостанция* — бәйләнеш тоту өчен билгеләнгән радиостанция.

**СВЯЗНО'Й** II *спец.* — связной (подразделение командирының турыдан-туры начальнигы белән бәйләнеш тоту өчен билгеләнгән гаскәри).

**СВЯ'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — бәйләнешлелек; *связность мыслей* — фикерләрнең берберсенә бәйләнешлелеге.

**СВЯ'ЗНЫЙ** — (логик һәм грамматик яктан) бәйләнешле, төзек; *связный рассказ* — төзек хикәя.

**СВЯ'ЗОЧНЫЙ** — бәйли торган, тоташтыра торган.

**СВЯЗУ'ЮЩИЙ** — бәйли торган, тоташтыра торган; *связующее звено* — тоташтыра торган буын.

**СВЯ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. связать.

**СВЯ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. связаться; 2. *страд.* тоташтырылу, бәйләп куелу.

**СВЯЗЬ** *ж.* — 1. бәйләнеш; *связь теории и практики* — теория белән практиканың бәйләнеше; 2. (*любовные отношения*) җенси бәйләнеш; 3. бәйләнеш, мөнәсәбәт, танышлык, белешлек; *дружеская связь* — дуслык бәйләнешләре; 4. элемтә; *поддерживать связь с тылом* — тыл белән элемтә тоту; *работники связи* — элемтә работниклары (телеграфта, почтада, радиода, телефонда эшләүчеләр); 5. (*скрепа*) ныгыткыч, беркеткеч. ◇ **В связи** *с чем* — ... белән бергә, сәбәпле, ... уңае белән; *покупательная способность увеличивается в связи с ростом благосостояния трудящихся* — хезмәт ияләренең тормышы яхшыру белән бергә аларның сатып алу сәләте арта.

**СВЯ'СЛО** *ср. обл.* — көлтә бавы.

**СВЯТИ'ЛИЩЕ** *ср. устар.* — гыйбадәтханә. ◇ **Святилище наук** *перен. ритор. устар.* — фәннәр мәхзәне (фән учреждениеләре турында әйтелә).

**СВЯ'ТКИ** *ед.* нет, *церк.* — святки бәйрәме (христианнарда рождество белән крещение арасындагы бәйрәм).

**СВЯ'ТО** *нареч.* — күз алмасыдай, зур ихтирам белән, хыянәтсез, изге күреп; *свято хранить тайну* — серне хыянәтсез саклау.

**СВЯТО'Й** — 1. *религ.* изге; *святой человек* — изге кеше; 2. *в знач. сущ. церк.* әүлия; 3. *перен.* изге, бөек, иң кыйммәт, иң кирәк, иң мөһим; *святая любовь к Родине* — Ватанга изге мәхәббәт; *святой долг* — изге бурыч. ◇ **Как бог свят** — әлбәттә, һичшиксез, һәрхәлдә. **Святой отец** или **владыка** *церк.* — изге ата (руханины зурлап әйтә торган сүз).

**СВЯ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — изгелек.

**СВЯТОТА'ТЕЦ** *м. церк. книж.* — динне мәсхәрәләүче, динне мәсхәрә итүче.

**СВЯТОТА'ТСТВЕННЫЙ** — динне мәсхәрә итү...-ы; *святотатственные слова* — динне мәсхәрә итү сүзләре.

**СВЯТОТА'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. (*богохульство*) динне мәсхәрә итү, динне мәсхәрәләү; 2. *перен.* (*оскорбление*) мыскыл итү, хурлау.

**СВЯТОТА'ТСТВОВАТЬ** *несов. устар.* — мәсхәрәләү, мыскыл итү, хурлау (изге нәрсәне).

**СВЯТО'ША** *м.* и *ж.*— 1. *(богомольный человек)* диндар, тәкъва; 2. *презрит. (лицемер, ханжа)* монафыйк, икейөзле кеше, суган суфые.

**СВЯТЫ'НЯ** *ж.*— 1. *церк.* изге әйбер; 2. *церк.* и *поэт.* изге урын; 3. *перен.* иң сөйкемле, иң кадерле, иң кыйммәтле нәрсә.

**СВЯЩЕ'ННИК** *м. церк.*— священник.

**СВЯЩЕННОДЕ'ЙСТВОВАТЬ** *несов.* — 1. *церк.* гыйбадәт кылу; 2. *перен. ирон.* тантаналы рәвештә башкару.

**СВЯЩЕННОСЛУЖИ'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.*— рухани.

**СВЯЩЕ'ННЫЙ** *книж.*— 1. *церк.* мөкатдәс, изге; 2. *перен.* изге; ***священный долг*** — изге бурыч.

**СГАРА'ЕМОСТЬ, СГАРА'ЕМЫЙ, СГАРА'ТЬ** — к. сгораемость, сгораемый, сгорать.

**СГИБ** *м.*— 1. *только ед. (действие)* к. сгибать; 2. бөгелгән урын, бөгелә торган урын, бөкләнгән урын; ***сгиб локтя*** — терсәкнең бөгелә торган урыны; ***лопнуло на сгибе*** — бөкләнгән урыннан шартлаган.

**СГИБА'ТЬ** *несов.*— к. согнуть.

**СГИБА'ТЬСЯ** *несов.*— к. согнуться.

**СГИ'БНУТЬ** *сов. разг. обл.*— һәлак булу.

**СГИ'НУТЬ** *сов. разг.*— югалу, юк булу, күздән югалу.

**СГЛА'ДИТЬ** *сов.*— 1. шомарту, тигезләү; ***сгладить неровности*** — кытыршы җирләрен шомарту; тигез булмаган җирләрен тигезләү; 2. *перен.* йомшарту, бетерү, сизелмәслек итү; ***сгладить противоречия*** — каршылыкларны йомшарту; 3. *перен.* шомарту, кытыршылыгын бетерү; ***сгладить стиль*** — стильне шомарту.

**СГЛА'ДИТЬСЯ** *сов.*— 1. тигезләнү, шомару; 2. *перен.* сизелмәслек булу, йомшару, бетү; ***противоречия сгладились*** — каршылыклар йомшарды.

**СГЛА'ДЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. сглодать.

**СГЛА'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— кимерелеп бетү.

**СГЛА'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. сгладить.

**СГЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. сгладиться; 2. *страд.* шомартылу, тигезләнү; 3. бетерелү, төзәтелү, йомшартылу.

**СГЛАЗ** *м. мн.* нет, *разг.*— күзегү, күз тию.

**СГЛА'ЗИТЬ** *сов.*— күзектерү, күз тидерү; ***не нужно очень хвалить, а то сглазим*** — бик мактарга ярамый, я күз тидерербез.

**СГЛОДА'ТЬ** *сов. разг.*— кимереп бетерү.

**СГЛОНУ'ТЬ** *сов. обл.*— йоту, йотып җибәрү.

**СГЛУПА'** *нареч. просторечь.*— к. сдуру.

**СГЛУПИ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— юләрлек эшләп ташлау.

**СГНА'ИВАТЬ** *несов.*— к. сгноить.

**СГНА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— черетелү, черетеп бетерелү.

**СГНЕСТИ'** *сов. обл. спец. просторечь.*— тыгызлау, тыгызлап кую, бастыру.

**СГНЕТА'ТЬ** *несов. обл. спец.*— к. сгнести.

**СГНИВА'ТЬ** *несов.*— к. сгнить.

**СГНИ'ТЬ** *сов.*— черү, череп бетү.

**СГНОИ'ТЬ** *сов.*— черетү, черетеп бетерү.

**СГОВА'РИВАТЬ** *несов. устар. обл.*— к. сговорить 1.

**СГОВА'РИВАТЬСЯ** *несов.*— к. сговориться.

**СГО'ВОР** *м.*— 1. *устар. (помолвка)* кыз ярәшү; 2. *неодобр. (соглашение)* сүз куешу, килешү, сүз беркетү.

**СГОВОРЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— сүз куешканлык, вәгъдә бергәнлек.

**СГОВОРИ'ТЬ** *сов.*— 1. *устар. обл.* ярәшү, кыз ярәшү; 2. к. сговориться.

**СГОВОРИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. сүз куешу; 2. анлашу, килешү; ***с ним трудно сговориться*** — аның белән килешүе кыен.

**СГОВО'РНЫЙ** *устар.*— кыз ярәшү...-ы; ***сговорный пир*** — кыз ярәшү мәҗлесе.

**СГОВО'РЧИВОСТЬ** *ж.*— сүзгә күнүчәнлек, килешүчәнлек.

**СГОВО'РЧИВЫЙ** — сүзгә күнүчән, килешүчән, килешеп була торган.

**СГОН** *м. мн.* нет — куып җыю, куып китерү; ***сгон скота на продажу*** — терлекләрне сатар өчен куып китерү.

**СГО'НКА** *ж. мн.* нет — 1. к. сгон; 2. агызу; ***сгонка плота по реке*** — елгада сал агызу.

**СГО'ННЫЙ** *обл. спец.*— 1. сал агызу...-ы, салчылар...-ы; ***сгонная работа*** — сал агызу эшләре; 2. куып җыелган, куып китерелгән; ***сгонные лошади*** — куып китерелгән атлар; 3. саллап агызу өчен хәзерләнгән, агызу өчен хәзерләнгән; ***сгонный лес*** — саллап агызу өчен хәзерләнгән агач.

**СГОНОШИ'ТЬ** *сов. обл.*— 1. җыеп кую; ***сгоношить деньги*** — акча җыеп кую; 2. (тиз генә) хәзерләп кую, хәзерләп алу.

**СГО'НЩИК** *м. спец.*— 1. куучы, агызучы; ***сгонщик плотов*** — сал агызучы; 2. *(гуртовщик)* мал куучы.

**СГОНЯ'ТЬ** *несов.*— к. согнать.

**СГОНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. куып җибәрелү, хезмәттән чыгарылу; 2. суда агызып төшерелү; 3. куып җыелу (бер җиргә).

**СГОРА'ЕМОСТЬ** *ж. спец.*— янучанлык, яну сәләте.

**СГОРА'ЕМЫЙ** *спец.*— яна торган.

**СГОРА'ТЬ** *несов.*— к. сгореть.

**СГО'РБИТЬ** *сов.*— бөкрәйтү.

**СГО'РБИТЬСЯ** *сов.*— бөкрәю, бөкреләнү.

**СГОРЕ'ТЬ** *сов.*— 1. яну, янып бетү; ***свеча сгорела*** — шәм янып беткән; 2. *разг.* ягуга тотылу, ягуга тотып бетерү, ягылу, (ягылып) бетү; ***за зиму 5 кубометров дров сгорело*** — кыш буена 5 кубометр утын ягылды (бетте); 3. яну, кызу, кызып бозылу (мәсәлән, амбардагы икмәк); 4. *обл.* яну (өй, каралтылар яну); 5. *перен. разг.* яну, һәлак булу; ***сгорел от водки*** — аракыдан янды. ◇ **Сгореть от стыда** — оялуыннан җир тишегенә керердәй булу.

**СГОРЯЧА'** *нареч. разг.*— кызып китеп, кызулык белән.

**СГОТО'ВИТЬ** *сов.*— хәзерләү, хәзерләп кую.

**СГРА'БИТЬ** *сов. обл.* — тырма белән җыю, тырма белән җыеп алу, тырмап җыеп алу; ***сграбить сено*** — печәнне тырма белән җыеп алу.

**СГРЕБА'ТЬ** *несов.*— к. сгрести.
**СГРЕБА'ТЬСЯ** I *несов.*— **1.** к. сгрестись I; **2.** *страд.* тырма белән җыелу; **3.** *страд.* көрәлү, көрәп төшерелү.
**СГРЕБА'ТЬСЯ** II *несов. спорт.*— (көймәдә) бергә ишәргә күнегү.
**СГРЕСТИ'** *сов.*— **1.** җыю, өеп кую (тырма, көрәк яки себерке белән өеп кую); *сгрести сено* — печәнне тырма белән өеп кую; **2.** көрәп төшерү, көрәп ташлау; *сгрести снег с крыши* — карны өй түбәсеннән көрәп төшерү; **3.** *просторечь. фам.* эләктереп алу, куä белән эләктереп алу.
**СГРЕСТИ'СЬ** I *сов.*— җыелу, өелү, бер өемгә өелү (көрәк, тырма яки себерке белән өемгә өеп куелу).
**СГРЕСТИ'СЬ** II *сов.* — к. сгребаться II.
**СГРУБИ'ТЬ** *сов. просторечь.*— к. нагрубить.
**СГРУДИ'ТЬСЯ** *сов. просторечь.*— өелешү, җыелышу, өелү, җыелу.
**СГРУЖА'ТЬ** *несов. спец.*— к. сгрузить.
**СГРУЖА'ТЬСЯ** I *несов. страд. спец.*— бушатылу.
**СГРУЖА'ТЬСЯ** II *несов. просторечь.*— к. сгрудиться.
**СГРУЗИ'ТЬ** *сов.*— бушатып бетерү; *сгрузили товары с судна* — суднодан товарларны бушатып бетерделәр.
**СГРУППИРОВА'ТЬ** *сов. книж.*— төркемләү, төркемнәргә берләштерү, төркемләп бетерү.
**СГРУППИРОВА'ТЬСЯ** *сов. книж.*— төркемләшү, төркемнәргә берләшү.
**СГРУСТНУ'ТЬСЯ** *сов. просторечь.*— к. взгрустнуться.
**СГРЫЗА'ТЬ** *несов. разг.*— к. сгрызть.
**СГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— кимереп бетерелү.
**СГРЫЗТЬ** *сов. разг.*— кимереп (ярып) ашап бетерү, кимереп бетерү; *сгрызть фунт орехов* — бер кадак чикләвек (ярып) ашап бетерү.
**СГУБИ'ТЬ** *сов. просторечь.*— һәлак итү, харап итү.
**СГУСТИ'ТЕЛЬ** *м. тех.*— **1.** куерткыч, куерту машинасы; **2.** куеландыру матдәсе.
**СГУСТИ'ТЬ** *сов.*— **1.** куерту; **2.** *перен. книж.* киеренкеләндерү, кискенләштерү; куерту; *сгустить атмосферу вокруг какого-н. вопроса* — берәр мәсьәлә тирәсендә атмосфераны куерту, мәсьәләне куерту. ◇ **Сгустить краски** *перен.*— күпертү, күпертеп җибәрү; *рассказывая, сгустил краски* – сөйләгәндә күпертеп сөйләде.
**СГУСТИ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** куеру; **2.** *перен.* кискенләшү, киеренкеләнү, куеру.
**СГУ'СТОК** *м.*— укмашкан (нәрсә), оешып каткан (нәрсә).
**СГУЩА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— куеручанлык, куера алучанлык.
**СГУЩА'ТЬ** *несов.*— к. сгустить.
**СГУЩА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. сгуститься; **2.** *страд.* куертылу.
**СДА'БРИВАТЬ** *несов.*— к. сдобрить.
**СДА'БРИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— тәмләндерелү.
**СДАВА'ТЬ** *несов.*— к. сдать.
**СДАВА'ТЬСЯ** I *несов.*— **1.** к. сдаться; **2.** *страд.* бирелү, тапшырылу; **3.** *страд.* кайтарып бирелү, сдача кайтарылу.
**СДАВА'ТЬСЯ** II *несов. разг.*— күренү, тоелу; *мне сдается, что он не придёт* — минемчә ул килмәс төсле тоела.
**СДАВИ'ТЬ** *сов.*— кысу; *сдавить руку до боли* — авырттырганчы кулны кысу.
**СДА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. сдавить.
**СДА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— кысылу.
**СДА'ВОЧНЫЙ** *тех.*— кыса торган, прессләый торган.
**СДА'ИВАТЬ** *несов.*— к. сдоить.
**СДА'ИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— савып алыну.
**СДА'ТОЧНЫЙ** *офиц.*— тапшыру ...-ы, тапшыра торган; *сдаточный пункт* — тапшыру пункты.
**СДА'ТЧИК** *м.*, **СДА'ТЧИЦА** *ж. офиц.*— тапшыручы.
**СДАТЬ** *сов.*— **1.** тапшыру, бирү; *сдать дела* — эшләрне тапшыру; **2.** (вакытлыча файдалануга) бирү; *сдать квартиру* — квартирны (вакытлыча файдалануга) бирү; **3.** кайтару, кайтарып бирү; *сдать с рубля мелочью* — бер сумнан вак акча кайтару; **4.** тарату, өләшү; *неправильно сдал карты* — карталарны дөрес таратмаган; **5.** бирү; *сдать позицию* — позицияне бирү; **6.** киметү, акрынайту; *не сдадим темпов* — темпларны киметмәбез; **7.** *разг.* бирешү; *боксёр сдал к финишу* — боксёр ахырга таба биреште; *он очень сдал после болезни* — ул авырудан соң бик бирешкән; **8.** *разг.* начаррак эшли башлау, бозылу; *мотор сдал* — мотор бозылды; **9.** *разг.* җиңелү, чигенү, бирешү; *он быстро сдал, не выдержав решительного нападения противника* — каршы якның кискен рәвештә ясалган һөҗүменә каршы тора алмыйча, ул бик тиз җиңелде; **10.** *спорт. воен.* чигенү, чигендерү, артка чигендерү (ат турында); **11.** *просторечь.* кайтару, кайтарып бирү (каршы сугу мәгънәсендә). ◇ **Зима уже сдала** *разг.*— кыш йомшарды.
**СДА'ТЬСЯ** I *сов.*— **1.** бирелү; *мятежники сдались* — фетнәчеләр бирелделәр; **2.** *обл.* йомшару; *зима сдалась* — кыш йомшарды; **3.** *просторечь. (уменьшиться в размере, объёме)* кечерәю, кимү; **4.** *мор. (отплыть назад)* ишеп чигенү; **5.** *обл.* чигенү, китү; *волки сдались в леса* — бүреләр урманнарга киттеләр (чигенделәр). ◇ **На кой леший сдался мне...** *просторечь. фам.*— ни шайтаныма кирәге бар...
**СДА'ТЬСЯ** II *сов. безл. разг.*— к. сдаваться II.
**СДА'ЧА** *ж.*— **1.** к. сдать 1, 2, 3, 4, 5, 6, 9, 10, 11; **2.** сдача, кайтарып бирелә торган акча. ◇ **Дать сдачи** *разг.*—кайтару, кайтарып бирү (каршы сугу яки каршы сүз әйтү).
**СДВА'ИВАТЬ** *несов.*— к. сдвоить.
**СДВА'ИВАТЬСЯ** *несов.*— к. сдвоиться 1.
**СДВИГ** *м.*— **1.** к. сдвинуть, сдвинуться; **2.** *геол.* күчү, күчеш; **3.** *перен.* үсеш, алга китеш, үзгәреш.
**СДВИГА'ТЬ** *несов.*— к. сдвинуть.
**СДВИГА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. сдвинуться;

2. *страд.* күчерелү, шудырып күчерелү; шудырып якынлаштырылу.

**СДВИЖНО'Й** — шудырмалы; *сдвижные дверцы* — шудырмалы капкач(лар).

**СДВИ'НУТЬ** *сов.*— 1. (шудырып) күчерү; этәреп кую, кузгату; *сдвинуть с места сундук* — сандыкны урыныннан кузгату; 2. *(двигая, свалить куда-н.)* шудырып төшерү, шудырып аудару; 3. янәшә китереп кую; янәшә кую; *сдвинуть столы* — өстәлләрне янәшә кую. ◇ **Сдвинуть брови** — кашларны җыеру. **Сдвинуть с места** *перен.*— урыныннан кузгату (берәр эшне тормышка ашыра башлау, берәр кешене хәрәкәтләнергә, эшләргә мәҗбүр итү).

**СДВИ'НУТЬСЯ** *сов.*— 1. (урыныннан) күчү, кузгалу, кузгалып китү; *судно сдвинулось с мели* — судно сайлыктан кузгалып китте; 2. җыерылу; *брови сдвинулись* — кашлары җыерылды.

**СДВО'ЕННОСТЬ** и **СДВОЁННОСТЬ** *ж.*— 1. ике катлангаплык; 2. икешәр-икешәр итеп тезелү (тезелгән булу).

**СДВО'ЕННЫЙ, СДВОЁННЫЙ** — 1. (ике) катланган; 2. ике рәт итеп тезелгән, икешәр-икешәр итеп тезелгән.

**СДВОИ'ТЬ** *сов.*— 1. ике кат итү, (ике) катлау; *сдвоить дратву* — җеп очын (ике) катлау; 2. *муз.* (бер-бер артлы) кабатлау; *сдвоить ноту* — нотаны кабатлау; 3. к. вздвоить.

**СДВОИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. ике катлану; *дратва сдвоилась* — җеп очы (ике) катланган; 2. *муз.* (бер-бер артлы) кабатлану; 3. *чаще безл.* ике булып күренү, куш булып күренү.

**СДЕВА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. сдеть.

**СДЕ'ЛАТЬ** *сов.*— к. делать.

**СДЕ'ЛАТЬСЯ** *сов.*— к. делаться.

**СДЕ'ЛКА** *ж.*— килешү, үзара сүз куешу. ◇ **Сделка с совестью** *перен.*— вөҗданга хыянәт итү.

**СДЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *экон.*— 1. эш башыннан түләү; *принцип сдельности*— эш башыннан түләү принцибы; 2. эш башыннан түләү системасы; *ввести сдельность* — эш башыннан түләү системасын кертү.

**СДЕ'ЛЬНЫЙ** — 1. эш башыннан...; *сдельная оплата* — эш башыннан түләү; 2. эш башыннан түләнә торган; *сдельная работа* — эш башыннан түләнә торган эш.

**СДЕ'ЛЬЩИК** *м.*— эш башыннан эшләүче.

**СДЕ'ЛЬЩИНА** *ж. мн.* нет — эш башыннан эшләү системасы; эш башыннан түләнә торган эш.

**СДЕ'ЛЬЩИЦА** *ж.*— к. сдельщик.

**СДЁРГАТЬ** *сов. разг.*— тарта-тарта төшерү, тарткалап төшерү.

**СДЁРГИВАТЬ** *несов.*— к. сдёрнуть.

**СДЁРГИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— тартып төшерелү, тартып алыну.

**СДЕ'РЖАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — тотнаклылык, үзен-үзе тота белү; сабырлык.

**СДЕ'РЖАННЫЙ** — 1. тотнаклы, сабыр, үзен-үзе тота белүчән; *сдержанный человек* — үзен-үзе тота белүчән кеше; 2. сабыр; *сдержанный тон* — сабыр тон.

**СДЕРЖА'ТЬ** *сов.*— 1. каршы тора алу, тотып тору, туктату; *сдержать натиск врага*— дошманның һөҗүменә каршы тора алу; 2. тотып калу, туктату; *сдержать лошадей* — атларны туктату; 3. *перен.* тыю, тыеп калу, тотып калу; *сдержать слёзы* — күз яшьләрен тыю. ◇ **Сдержать слово** (клятву, обещание)— сүзендә тору, вәгъдәсендә тору.

**СДЕРЖА'ТЬСЯ** *сов.*— тыелу, тыелып калу, үзен-үзе тыеп калу, чыдау, түзү.

**СДЕ'РЖИВАТЬ** *несов.*— к. сдержать.

**СДЕ'РЖИВАТЬСЯ** *несов.*—к. сдержаться.

**СДЁРНУТЬ** *сов.*—1. (тиз генә) салып ташлау, тиз генә салдыру; *сдёрнуть шинель* — шинельне тиз генә салып ташлау; 2. тартып төшерү, тартып алу; *сдёрнуть одеяло с кровати* — одеялны кроватьтан тартып төшерү; 3. *простореч.* тартып кую; *сдёрнуть кисет* — тәмәке янчыгының авызын тартып кую.

**СДЕТЬ** *сов. простореч.*— салу, салып кую; *сдеть шпагу* — кылычны салып кую.

**СДИРА'ТЬ** *несов. разг.*— к. содрать 1.

**СДИРА'ТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. содраться; 2. *страд.* куптарылу, каезлану.

**СДИ'РОЧНЫЙ** *спец.*— каезлау...-ы, куптару...-ы; *сдирочный инструмент* — каезлау инструменты.

**СДИ'РЩИК** *м. спец.*—1. кабык каезлаучы; 2. тире тунаучы.

**СДО'БА** *ж. мн.* нет — сдоба (1. камырга кушыла торган май, каймак һ. б.; 2. *собир.* шундый камырдан пешерелгән күмәчләр).

**СДО'БИТЬ** *несов. разг.*— сдоба салу (камырга май, каймак, сөт, йомырка һ. б. салу).

**СДО'БНЫЙ** — 1. сөткә-майга куелган, сөт-май кушып (изелгән) пешерелгән; *сдобное тесто* — сөткә-майга куелган камыр; 2. *перен. разг. шутл.* тутырган тавык кебек (таза, симез).

**СДО'БРИТЬ** *сов.*— тәмләндерү.

**СДОБРОВА'ТЬ: не сдобровать** *разг.*— яхшы булмас, яхшылык күрмәс, исән-сау калмас.

**СДОИ'ТЬ** *сов.*— савып алу.

**СДОЙ** *м. обл.*— угызлы сөт.

**СДО'ЙНЫЙ** *обл.*— угызлы; *сдойное молоко* — угызлы сөт.

**СДО'ХНУТЬ** *сов. простореч. вульг.*— к. издохнуть.

**СДРЕ'ЙФИТЬ** *сов. простореч. фам.*— куркып калу, шүрләп калу.

**СДРЕЙФОВА'ТЬ** *сов.*—1. *мор.* к. дрейфовать 1. 2; 2. *простореч. фам.* к. сдрейфить.

**СДРЕ'ФИТЬ** *сов.*— к. сдрейфить.

**СДРУЖА'ТЬ** *несов. редко* — к. сдружить.

**СДРУЖА'ТЬСЯ** *несов.*— к. сдружиться.

**СДРУЖИ'ТЬ** *сов.*— дуслаштыру, дусландыру.

**СДРУЖИ'ТЬСЯ** *сов.*— дуслашу, дуслану.

**СДУВА'ТЬ** *несов.*— к. сдуть.

**СДУВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— өреп төшерелү.

**СДУ'НУТЬ** *сов. однокр. разг.*— к. сдуть 1.

**СДУРИ'ТЬ** *сов. простореч. фам.*— ахмаклык эшләү, ахмакалык эшләп ташлау.

**СДУ'РУ** *нареч. разг. неодобр.*— ахмаклыктан, аңгыралыктан, юләрлектән, аңгыралык (тинтәклек) аркасында, аңгыралык белән, юләрлек белән, аңгыраланып.

**СДУТЬ** *сов.*—1. өреп төшерү; *сдуть пыль со стола* — өстәлдән тузанны өреп төшерү; 2. *(ветром)* очыру, очырып алып китү (җил белән); 3. *школьн. арго* к. списать 3.

**СДЫХА'ТЬ** *несов. простореч. вульг.* — к. сдохнуть.

**СЕ** *указ. частица церк.-книж., поэт. устар.*— к. вот.

**СЁ** *местоим. указ.*: **то да сё** — к. тот; **ни то, ни сё** — к. тот; **ни с того, ни с сего** — к. тот; **о том, о сём** — төрле нәрсәләр турында.

**СЕА'НС** *м.*— сеанс (1. билгеле вакыт эчендә берәр нәрсәне күрсәтү, мәсәлән, спектакльне, кинофильмны; *пошёл в кино на последний сеанс* — киногa соңгы сеанска китте; 2. берәр эш эшләнгән арада үткән вакыт; 3. *устар.* утырыш, җыелыш; *спиритический сеанс* — спиритик сеанс).

**СЕАНСЁР** *м. спец.*— сеансёр (сеанс бирүче кеше).

**СЕБЕ** *без удар. разг.*: **идёт себе, ничего не замечая** — бара шунда, берни дә күрмичә; **давай, думаю себе, посмотрю** — әйдә, карап карыйм әле, дип уйладым үз-үземә; **ничего себе** — к. ничего 3; **так себе** — к. так.

**СЕБЕДОВЛЕ'ЮЩИЙ** *книж. устар.* — к. самодовлеющий.

**СЕБЕСТО'ИМОСТЬ** *ж. эк.*— үзкыйммәт; *борьба за снижение себестоимости* — үзкыйммәтне төшерү өчен көрәш.

**СЕБЯ'** *местоим. возвр.*— үземне, үзеңне, үзен. ◇ **Владеть собой** — к. владеть. **Овладеть собой** — к. овладеть. **Вне себя** — үз-үзен белми (берәр нәрсә эшләп ташлау). **За собой** — артымда, артыңда, артында. **Из себя выходить** — к. выйти. **Не в себе** *простореч.* — кәефе(м) юк, борчылып тора(м). **Не по себе** *устар. разг.*—1. кәефе(м) юк, хәле(м) юк, авырсынып тора(м); 2. уңайсызлану, үзеңне уңайсыз хәлдә сизү. **По себе** —1. көчеңә карап; *с отриц.* үзенә күрә түгел; 2. үзеңнән соң. **Прийти в себя** — аңга килү, һушка килү. **Про себя** — 1. әкрен генә, кычкырмыйча; 2. эчтән (уйлау, белеп тору). **Сам по себе** — үзеннән-үзе. **Сам собою, сама собою, само собою** — үзеннән-үзе. **Само собою разумеется** *вводн. сл.*— билгеле, һичшиксез. **Себе на уме** *разг.*— астыртын, хәйләкәр. **У себя** — үзеңдә, үз өеңдә, үз бүлмәсендә (үзеңдә, үз өеңдә, үз бүлмәңдә, үз өемдә, үз бүлмәмдә һ. б.).

**СЕБЯЛЮ'БЕЦ** *м. книж. устар.*— үзенсөяр, үзен генә яратучы, эгоист.

**СЕБЯЛЮБИ'ВЫЙ** *книж.*— үзен генә яратучы, үзен генә сөюче, үзе турында гына кайгыртучы.

**СЕБЯЛЮ'БИЕ** *ср. мн. нет, книж.*— үзен генә сөю, үзе турында гына кайгырту, эгоизм.

**СЕВ** *м. мн. нет* — чәчү; *подготовка к весеннему севу* — язгы чәчүгә хәзерлек.

**СЕВА'ЛКА** *ж. обл.*— (иген) чәчү тубалы.

**СЕВА'ЛЬНИК** *м. обл.*— к. севалка.

**СЕ'ВАЛЬЩИК** *м. обл.*— к. севец.

**СЕ'ВЕР** *м. мн. нет* — төньяк.

**СЕ'ВЕРНЫЙ** — 1. төньяк..., төньяк...-ы; *северный полюс* — төньяк полюс; 2. төньяктагы, төньякта яшәүче; *северные люди* — төньякта яшәүче кешеләр.

**СЕ'ВЕРО-ВОСТО'К** *м. мн. нет* — төньяк-көнчыгыш.

**СЕ'ВЕРО-ВОСТО'ЧНЫЙ** —1. төньяк-көнчыгыш...-ы, төньяк-көнчыгыштагы; *северо-восточные области* — төньяк-көнчыгыштагы өлкәләр; 2. төньяк-көнчыгыштан исә торган; *северо-восточный ветер* — төньяк-көнчыгыштан исә торган җил.

**СЕ'ВЕРО-ЗА'ПАД** *м. мн. нет* — төньяк-көнбатыш.

**СЕ'ВЕРО-ЗА'ПАДНЫЙ** —1. төньяк-көнбатыш...-ы, төньяк-көнбатыштагы; *северо-западные области* — төньяк-көнбатыштагы өлкәләр; 2. төньяк-көнбатыштан исә торган; *северо-западный ветер*— төньяк-көнбатыштан исә торган җил.

**СЕВЕРОМО'РЕЦ** *м.*— Төньяк диңгез флотында хезмәт итүче.

**СЕВЕРЯ'НИН** *м.*—1. төньяк кешесе, төньякта яшәүче кеше; 2. *только мн. истор.* северяннар (Десна елгасы бассейнында яшәгән борынгы славян кабиләсе).

**СЕВЕРЯ'НКА** *ж.*— к. северянин 1.

**СЕВЕ'Ц** *м. обл. спец.*— (иген) чәчүче.

**СЕВО'К** *м. обл.*— (кул белән чәчкәндә ташлана торган) бер уч орлык.

**СЕВООБОРО'Т** *м. с.-х.*— чәчү әйләнеше.

**СЕВР** *м. мн. нет* — севр (югары художестволы фарфор әйбер).

**СЕ'ВРСКИЙ** *ж.* — севр...-ы; *севрская ваза* — севр вазасы.

**СЕВРЮ'ГА** *ж.*— севрюга, укбаш, укборын (балык).

**СЕВРЮ'ЖИЙ** — 1. севрюга...-ы, укбаш...-ы, укборын...-ы; *севрюжий пузырь* — севрюга куыгы; 2. севрюга...-ы, севрюга (укбаш, укборын) салып пешерелгән; *севрюжья уха* — севрюга шулпасы.

**СЕВРЮ'ЖИНА** *ж. мн. нет* — севрюга (укбаш, укборын) ите.

**СЕ'ВЩИК** *м. обл.* — к. севец.

**СЕГМЕ'НТ** *м.*—1. *мат.* сегмент; 2. *биол.* буынтык.

**СЕГМЕНТА'ЦИЯ** *ж. мн. нет, биол.*— буынтыклану.

**СЕГО'ДНЯ** *нареч.*—бүген. ◇ **Не сегодня-завтра** — бүген булмаса иртәгә, якын арада.

**СЕГО'ДНЯШНИЙ**—бүгенге; *сегодняшний день* — бүгенге көн.

**СЕГОЛЕ'ТКА** *ж. спец.*— яшь маймыч (бер яшьлек вак балык).

**СЕДА'ЛИЩЕ** *ср.*—1. *анат.* утракса, арт

сан; 2. *книж. торж.* утыргыч, урындык; тәхет.

**СЕДА'ЛИЩНЫЙ** *анат.*— утракса...-ы; *седалищный нерв*— утракса нервы.

**СЕДЁЛКА** *ж.*— ынгырчак.

**СЕДЕ'ЛЬНИК** *м.*—иярләр) ясаучы (оста).

**СЕДЕ'ЛЬНЫЙ** — ияр...-ы; *седельная лука* — ияр агачы.

**СЕДЕ'ЛЬЦЕ** *ср.*— к. седло.

**СЕДЕ'ЛЬЧАТЫЙ** — иярсыман.

**СЕДЕ'ТЬ** *несов.*— чал керү, чәч (сакал) агару, чәч (сакал) агара башлау.

**СЕДИНА'** *ж.*—1. чал, ак чәч; 2.*чаще мн. перен. книж. поэт.* картлык, ак чәч; *смеёшься над сединами* — карт башымнан көләсең, ак чәчемнән көләсең; 3 *только ед.* ак төкләр; *седина в бобре дорого ценится* — ак төкләр катнашкан кондыз мехы кыйммәт йөри.

**СЕДИ'НКА** *ж. разг. фам.*— ак чәч бөртеге, ак чәч.

**СЕДЛА'ТЬ** *несов.*— иярләү.

**СЕДЛА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— иярләнү.

**СЕДЛИ'СТЫЙ** — батынкы билле; *седлистая лошадь* — батынкы билле ат.

**СЕДЛО'** - 1. ияр; 2. к. седловина 2.

**СЕДЛОВИ'НА** *ж.*— бил (1. *спец.* хайван аркасының ияр куела торган батынкы җире; 2. *геогр.* тауның билләнеп торган урыны).

**СЕДМИ'ЦА** *ж. церк.-книж. устар.* — атна.

**СЕДОБОРО'ДЫЙ** — чал сакаллы, ак сакаллы.

**СЕДОБРО'ВЫЙ** *редко* — кашлары агарган, кашларына чал кергән.

**СЕДОВЛА'СЫЙ** *поэт.*, **СЕДОВОЛО'СЫЙ** — чал чәчле, ак чәчле.

**СЕДО'Й** — 1. чал, агарган, ак; *седая борода* — чал сакал; 2. чал чәчле, чәче агарган, ак чәчле; *седой старик* — чал чәчле карт; 3. соры, соры төстәге; *седое сукно* — соры постау. ◇ **Дожить до седых волос**— картайганчы яшәү. **Седая старина** *книж.*— борын заман.

**СЕДО'К** — *м.*— 1. утырып баручы (кучер); 2. *(всадник)* жайдак, атлы, атка атланган кеше, ат менгән кеше.

**СЕДОУ'СЫЙ** — мыеклары агарган, чал мыеклы.

**СЕДЬМО'Й** — жиденче. ◇ **Седьмая вода на киселе** — к. кисель. **Быть на седьмом небе** — к. небо.

**СЕЗА'М** *м. бот.*— кунжут. ◇ **Сезам, откройся!** *шутл.*— сезам, сереңне ач! Симсим, ачыл!

**СЕЗА'МОВЫЙ** — кунжут.. -ы; *сезамовое масло* — кунжут мае.

**СЕЗО'Н** *м.*— сезон (1. елның дүрт вакытының берсе; *зимний сезон* — кышкы сезон; 2. билгеле бер эш эшләнә торган чор; 3. билгеле бер җимеш, яшелчә һ. б. өлгерә торган вакыт; *сезон винограда ещё не наступил* — виноград сезоны килеп җитмәде әле).

**СЕЗО'ННИК** *м.*— сезонлы эшче.

**СЕЗО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — сезонлы булу, сезонлылык.

**СЕЗО'ННЫЙ** — 1. сезон...-ы, сезонлы; *сезонные работы* — сезонлы эшләр; *сезонный товар* — сезонлы товар; 2. бер сезонлык...; *сезонный билет* — бер сезонлык билет.

**СЕЙ** *книж. устар. ритор., офиц., теперь ирон.*— бу, шушы, шул, ошбу.

**СЕЙМ** *м. полит.*— сейм (1. кайбер дәүләтләрдә – парламент; 2 *истор.* сословиеләр вәкилләре җыелышы).

**СЕ'ЙНЕР** *м. спец.*— сейнер (траулер тибындагы балык тоту судносы).

**СЕЙСМИ'ЧЕСКИЙ** *геол.*— сейсмик; *сейсмические приборы* — сейсмик приборлар. ◇ **Сейсмические области** — җир тетрәү була торган өлкәләр. **Сейсмические явления** — җир тетрәү күренешләре.

**СЕЙСМОГРА'ММА** *м. геол.*— сейсмограмма (җирдәге тирбәнүләрнең, җир тетрәвенең сейсмограф ярдәмендә язылган кәкре сызыгы).

**СЕЙСМО'ГРАФ** *м. геол.*— сейсмограф (җир өстендәге тирбәлешләрне, җир тетрәвен автоматик рәвештә яза торган махсус прибор).

**СЕЙСМОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *геол.*— сейсмографик; *сейсмографические записи* — сейсмографик язмалар.

**СЕЙСМОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет, *геол.*— сейсмография (1. җир кабыгы тирбәлешләрен, җир тетрәвен сейсмограф ярдәмендә язып алу; 2. к. сейсмология).

**СЕЙСМОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *геол.*— сейсмологик; *сейсмологические исследования* — сейсмологик тикшеренүләр.

**СЕЙСМОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *геол.*— сейсмология (геологиянең җир кабыгы тирбәлешләрен, җир тетрәвен өйрәнә торган бүлеге).

**СЕЙСМО'МЕТР** *м. геол.*— сейсмометр (җир кабыгы тирбәлешләрен, җир тетрәвен күзәтү өчен хезмәт итә торган прибор).

**СЕЙСМОМЕТРИ'ЧЕСКИЙ** — сейсмометрик; *сейсмометрические наблюдения* — сейсмометрик күзәтүләр.

**СЕЙСМОМЕ'ТРИЯ** *ж. геол.*— сейсмометрия (җир кабыгы тирбәлешләрен үлчәү турындагы фән).

**СЕЙФ** *м.*— сейф (кыйммәтле әйберләр саклый торган янмас шкаф, ящик яки махсус бина).

**СЕЙЧА'С** *нареч.*— 1. хәзер; *сейчас приду* — хәзер килермен, хәзер киләм; 2. *разг.* хәзер үк, бер караштан ук; *сейчас видно, что он умный парень* — егетнең акыллылыгы хәзер үк сизелеп тора; 3. *разг.* (*тотчас же, непременно*) шунда ук; 4. хәзер, хәзерге вакытта; *сейчас они живут хорошо* — хәзер алар яхшы торалар.

**СЕКА'РЬ** *м. спец.*— к. секач 3, 4.

**СЕКА'ТОР** *м. с.-х.*— секатор, ботак кискеч, бакча кайчысы.

**СЕКА'Ч** *м.*— 1. *тех.* секач, тимер кискеч (чүкечнең бер төре); 2. *охот. обл. (самец

*у зверей)* ата җәнлек, ата җанвар; 3. *спец.* торф кискеч; 4. *спец.* торф кисүче (эшче).

**СЕКВЕ'СТР** *м.*— секвестр (1. *право, офиц.* нинди дә бер милектән файдаланудан вакытлыча тыю, милеккә вакытлыча арест салу; 2. *мед.* нинди дә бер органның, мәсәлән, сөякнең үле хәләнә килгән өлеше).

**СЕКВЕСТРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. право офиц.*— к. секвестровать.

**СЕКВЕСТРИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. право офиц.*— к. секвестроваться.

**СЕКВЕСТРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. право, офиц.*— (милеккә) вакытлыча арест салу.

**СЕКВЕСТРОВА'ТЬСЯ** *несов. право офиц.*— (милеккә) вакытлыча арест салыну.

**СЕКИ'РА** *ж.*— 1. *поэт. ритор.* (*топор*) балта; 2. *истор.* ай балта, секира (борынгы корал).

**СЕКРЕ'Т** I *м.*— 1 сер; 2. *воен.* секрет (дошман күрмәслек урында яшеренеп күзәтеп торучы хәрби пост); 3. *охот. обл.* к. тайник 2.

**СЕКРЕ'Т** II *м. физиол.*— секрет, биз сыекчасы.

**СЕКРЕТАРИА'Т** *м.*— 1. секретарьлар; 2. секретариат (берәр төрле учреждение, оешма каршында оештыру-башкару характерында булган агымдагы эшләрне алып баручы бүлек. орган).

**СЕКРЕТА'РИТЬ** *несов. простореч. шутл.*— к. секретарствовать.

**СЕКРЕТА'РСКИЙ** — секретарь...-ы, секретарьлар...-ы; *секретарская обязанность* — секретарь бурычы, секретарь вазифасы.

**СЕКРЕТА'РСТВО** *ср.*— секретарьлык.

**СЕКРЕТА'РСТВОВАТЬ** *несов.*— секретарь булып эшләү, секретарь вазифасын үтәү.

**СЕКРЕТА'РША** *ж. разг.*— 1. секретарь (хатын-кыз); 2. *устар.* секретарь хатыны.

**СЕКРЕТА'РЬ** *м* — секретарь.

**СЕКРЕТЕ'Р** *м.*— секретер (1. *только ед.* сүзләрнең баш хәрефләре буенча бөтен бер җөмләне табудан гыйбарәт уен; 2. язу өстәленең бер төре).

**СЕКРЕТИ'Н** *м. физиол.*— секретин (ашказаны асты бизенең суын бүлдереп чыгара торган гормон).

**СЕКРЕ'ТКА** *ж. разг.*— секретка (читен ябыштырып, конвертсыз җибәрелә торган почта кәгазе).

**СЕКРЕ'ТНИЧАТЬ** *несов. разг.*— 1. сер итеп тоту, яшерү; *что секретничать, всё равно узнаем!*— нигә яшерергә, барыбер белербез! 2. серләшү; *секретничали, сидя в углу* — бер почмакта утырып серләшә иделәр.

**СЕКРЕ'ТНО** *нареч.*— яшерен, яшертен, серле рәвештә.

**СЕКРЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— серлелек, яшеренлек.

**СЕКРЕ'ТНЫЙ** — серле, яшерен; *секретный приказ* — яшерен приказ.

**СЕКРЕ'ЦИЯ** *ж. физиол.*— секреция (биз сыекчасының эшләнү һәм бүленеп чыгу процессы).

**СЕКСАГОНА'ЛЬНЫЙ** *мат.*— алты почмаклы.

**СЕКСТА'НТ** *м. астр. геод.*— секстант (геодезия һәм астрономиядә кулланыла торган почмак үлчәгеч инструмент).

**СЕКСТЕ'Т** *м. муз.*— секстет (алты тавыш яки алты инструмент өчен язылган музыкаль әсәр).

**СЕКСТИЛЬО'Н** *м.*— секстильон (берлек цифрыннан һәм 21 нольдән гыйбарәт булган сан).

**СЕКСТИ'НА** *ж. лит.*— секстина (алты юллы строфалардан тора торган шигырьнең бер төре).

**СЕКСУАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— сексуализм (җенси тойгыларның артыклыгы).

**СЕКСУА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— җенси, сексуаль.

**СИГНАРА'НТ** *м.*, **СИГНАРА'НТКА** *ж. спец.*— к. сигнатурщик.

**СИГНАТУ'РА** *ж. апт.*— сигнатура (1. даруны ничек эчү турында рецептта язылган язу; 2. аптекадан дару белән бергә бирелә торган рецепт күчермәсе; 3. *тип.* типографиядә басылган һәр табакның тәртип номерын күрсәтә торган цифр).

**СИГНАТУ'РНЫЙ** — сигнатура...-ы; *сигнатурный ярлык* — сигнатура ярлыгы.

**СИГНАТУ'РЩИК** *м.*, **СИГНАТУ'РЩИЦА** *ж. спец.*— сигнатурчы (рецептларны сигнатураларга күчереп язучы).

**СИГО'ВИНА** *ж. мн.* нет, *разг.* — сиг балыгы ите, ала балык ите.

**СИГО'ВЫЙ** — сиг...-ы, ала балык...-ы; *сиговая икра* — сиг уылдыгы.

**СИДЕ'ЛЕЦ** *м.*— 1. *обл.* йомышчы, йомышка йөрүче; каравылчы; 2. *устар.* өлкән приказчик.

**СИДЕ'ЛКА** *ж.*— сиделка (больницада авырулар карачы хатын-кыз).

**СИДЕ'ЛЫЙ** *обл.*—утыра торган, утырган.

**СИДЕ'ЛЬЧЕСКИЙ** *устар.*— өлкән приказчик...-ы; *сидельческая должность* — өлкән приказчик урыны.

**СИ'ДЕНИЕ** *ср. только ед.* — 1. *(действие)* к. сидеть; 2. утыргыч.

**СИ'ДЕНЬ** *м. простореч.*— утырак, һәрвакыт утырып торучы (йөри алмаучы яки йөрергә яратмаучы кеше). ◇ **Сиднем сидеть** *разг.*— 1. тора алмыйча утыру (йөри алмау сәбәпле һәрвакыт утырып тору); 2. урыныннан да тормыйча утыру (беркая да чыкмау, өйдә генә утыру).

**СИДЕ'ТЬ** I *несов.*— утыру, утырып тору. ◇ **Вот где сидит** *перен. разг.*— менә кайда утыра (ул), бер имгәк булды инде, теңкәгә тиеп бетте. **Сидеть у моря, ждать погоды** *разг. ирон.*— аяз көнне яңгыр көтү. **Сидеть на яйцах** (о птице) — йомырка басу, бала (чебеш) чыгару.

**СИДЕ'ТЬ** II *несов. обл.*— куу (мәсәлән, дегет турында); *сидеть дёготь* — дегет куу.

**СИДЕ'ТЬСЯ** I *несов. безл. разг.*— утырасы килү; *ему не сиделось* — аның утырасы килми иде.

**СИДЕ'ТЬСЯ** II *несов. страд. обл.*—куылу (мәсәлән, дегет турында).

**СИДМЯ'** *нареч.*: **сидмя сидеть** — к. сидень.

**СИДР** *м.*— сидр (алма суын әчетеп ясалган вино).

**СИДЯ'ЧИЙ** — 1. утырган, утырып тора торган; *в сидячем положении* — утырган хәлдә, утырган килеш; 2. *перен.* урыныннан кузгалмый яшәүче; *сидячие животные* — урыныннан кузгалмый яшәүче хайваннар; 3. *разг.* утыру өчен билгеләнгән; *сидячие места* — утыру өчен билгеләнгән урыннар.

**СИЕНИ'Т** *м. мин.*— сиенит (тау токымы).

**СИЕ'Н(Н)А** *ж. мн.* нет — сиенна (куе сары төстәге буяу).

**СИЕ'Н(Н)СКИЙ: сиен(н)ская земля** — к. сиен(н)а.

**СИЗА'РЬ** *м.*— 1. *(дикий голубь)* урман күгәрчене, ала тоба, әберчен; 2. *(сизый голубь)* күк күгәрчен.

**СИЗЕ'ТЬ** *несов.*— күгелҗем төскә керү, күгелҗемләнү, күгелҗемләнеп тору.

**СИЗИ'ФОВ: Сизифов труд** или **Сизифова работа** — к. работа.

**СИЗОКРЫ'ЛЫЙ** — күк канатлы.

**СИ'ЗЫЙ** —күк, тонык күк, күгелҗем (төс).

**СИККАТИ'В** *м. тех.*— сиккатив (тизрәк кипсеннәр өчен олифка, лакка, майлы буяуларга кушыла торган матдә).

**СИКО'З** и **СИКО'ЗИС** *м. мед.*— сикоз (сакал-мыек арасына чыккан бетчәләр, сыткылар).

**СИКОФА'НТ** *м.* — 1. *книж. презрит.* яла ягучы, әләкче, чагучы, донос ясап торучы; 2. *зоол.* яшел коңгыз.

**СИКУ'РС** *м. воен. стар.*— ярдәм.

**СИ'ЛА** *ж.*— 1. көч; 2. *простореч.* бик күп, хисапсыз күп; *народу там — сила* — анда халык бик күп. ◇ **Взять силу** *простореч.*— көчәю, көчәеп китү. **Войти в силу** — 1. көчәю, көчәеп китү; 2. гамәлгә керү (закон турында); 3. *перен.* авторитеты көчәю, авторитеты арту. **В силах** — 1. хәл(ен)дә; *пока я в силах, поработаю* — хәлемдә чакта эшләрмен әле; 2. ...-а алу, хәленнән килү, кулыннан килү; *только содержащий все общество класс пролетариев в силах произвести социальную революцию* — тик бөтен җәмгыятьне асраучы пролетарийлар сыйныфы гына социаль революцияне ясый ала. **В силе** — 1. көчле; 2. *простореч.* кызу чак, кызып киткән чак; *игра уж в самой силе* (Лермонтов) — уенның иң кызып киткән чагы. **В силу** *устар.*— кулыннан килә, көченнән килә, хәленнән килә. **В силу** (всилу) чего *книж.*— аркасында, сәбәпле. **Лошадиная сила** *физ.*— к. лошадиный. **Нечистая сила** — к. нечистый. **От силы** *простореч.*— иң күбе, күп дигәндә. **По мере сил** — к. мера. **По силам, по силе** — көченә күрә. **По силе возможности** — мөмкин булган кадәрле, мөмкин булганынча, көч житкән кадәрле, куллан килгән хәтле, кулдан килгәнечә. **Под силу** — көче(м, н) житәрлек, көче(м, н) җитә. **Рабочая сила** — к. рабочий II. **Сил нет** — 1. көче(м,н) җитми, хәле(м,н) җитми; 2. *перен. разг. фам.* чыдар хәл юк. **Силою вещей** *книж.*— булган шартлар буенча, булган шартлар сәбәпле, барлыкка килгән шартлар буенча. **Через силу** — хәлдән тыш, көчтән тыш. **Что есть силы** или **что было силы** (или **сил**) *разг.*— бөтен көченә, бар көче белән.

**СИЛА'Ч** *м.*, **СИЛА'ЧКА** *ж.*— бик көчле кеше.

**СИЛИКА'Т** *м.*— силикат (1. *мин. хим.* кремнезём кушылмалары рәтенә керә торган минералларның гомуми исеме; 2. кирпеч, фарфор, пыяла кебекләрнең гомуми исеме).

**СИЛИКАТИЗА'ЦИЯ** *ж.*, **СИЛИКАТИ'РОВАНИЕ** *ср. тех.*— к. силикатировать.

**СИЛИКАТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.*— силикатлау.

**СИЛИКАТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. тех.*— силикатлану.

**СИ'ЛИТЬСЯ** *несов. разг.*— тырышу, тырышып карау, көчәнү, маташу.

**СИЛИ'ЦИЙ** *м. мн.* нет — к. кремний.

**СИЛКО'ВЫЙ** — тозакка эләккән, тозакка тотылган, тозак белән тотылган.

**СИЛКО'М** *нареч. простореч.*— к. силой.

**СИЛЛАБИ'ЧЕСКИЙ** *лит.* — силлабик (иҗекләр санына нигезләнгән).

**СИЛЛА'БО-ТОНИ'ЧЕСКИЙ** *лит.*—силлабо-тоник (иҗекләр санына һәм басымнарның билгеле бер тәртип белән урнашуына нигезләнгән).

**СИЛЛОГИ'ЗМ** *м. филос.*— силлогизм (формаль логикада — ике хөкем нигезендә өченчене чыгару).

**СИЛЛОГИ'СТИКА** *ж. мн.* нет—силлогистика (1. *филос.* силлогизмнар турындагы тәгълимат; 2. *перен. книж. ирон.* практик әһәмияте булмаган гомуми фикер йөртүләр).

**СИЛО'** *ср. обл.*— к. силок.

**СИЛОВО'Й** — көч таләп итә торган; *силовая работа* — көч таләп итә торган эш. ◇ **Силовая станция** — электр станциясе.

**СИ'ЛОЙ** *нареч. разг.*— көчләп, ирексезләп.

**СИЛО'К** *м.*— тозак.

**СИЛО'М** *нареч. обл.*— к. силой.

**СИЛОМЕ'Р** *м.*— көч үлчәгеч.

**СИ'ЛОС** *м. с.-х.* — силос (1. мал азыгын ачыта һәм саклый торган башня, чокыр; 2. шундый ысул белән әзерләнгән мал азыгы).

**СИ'ЛОСНЫЙ** *с.-х.* — силос...-ы; *силосная башня* — силос башнясы.

**СИЛОСОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. с.-х.*—силослау (мал азыгы турында).

**СИЛОСОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.* — силослану (мал азыгы турында).

**СИ'ЛОЮ** *нареч.*— к. силой.

**СИЛУЭ'Т** *м.*— силуэт (1. кешенең яки әйбернең сурәтен икенче бер төстәге фонда төшерү; 2. *перен.* берәр нәрсәнең карангыда, томанда күренгән шәүләсе).

**СИЛУЭТИ'СТ** *м.*, **СИЛУЭТИ'СТКА** *ж.*— силуэтлар ясаучы (художник).

**СИЛУЭ'ТКА** *ж. разг. устар.*— к. силуэт 1.

**СИЛУЭ'ТНЫЙ** — силуэт(лар) ясау...-ы; *силуэтное искусство* — силуэтлар ясау сәнгате.

**СИ'ЛЬНО** *нареч.*— 1. каты, нык, көчле, көчле рәвештә; *сильно сказано* — каты әйтелгән; 2. бик, бик нык, бик каты; *сильно испугать* — бик нык куркыту.

**СИЛЬНОДЕ'ЙСТВУЮЩИЙ** *книж. спец.*— көчле, көчле тәэсир итә торган.

**СИ'ЛЬНЫЙ** — 1. көчле, куәтле; *сильный человек* — көчле кеше; *сильное государство* — куәтле (көчле) дәүләт; 2. көчле, нигезле, төпле, әһәмиятле; *сильное доказательство* — нигезле дәлил; 3. бик зур, тирән; *я был в сильном горе в эту минуту* — мин бу минутта тирән кайгыда идем.

**СИЛЬФ** *м. книж.*— сильф (кельтлар һәм германиялеләр мифологиясендә — һава стихиясен гәүдәләндерә торган бик җинел һәм гадәттән тыш хәрәкәтчел мифик зат).

**СИЛЬФИ'ДА** *ж.*— 1. *книж.* к. сильф; 2. *перен. книж. устар.* сильфида, зифа буйлы хатын (кыз); 3. *только мн. зоол.* үләксә коңгызлары.

**СИМБИО'З** *м. биол.*— симбиоз (ике яки берничә организмның бер-берсенә ярдәм итеп бергә яшәве).

**СИМБИО'НТ** *м. биол.*— симбионт (симбиоз составына керә торган организм).

**СИ'МВОЛ** *м.* — символ (1. берәр төрле төшенчәнең шартлы билгесе булып хезмәт итә торган предмет яки хәрәкәт; *голубь — символ мира* — күгәрчен — тынычлык символы; 2. *лит., искус.* идеяләрне һәм тойгыларны шартлы рәвештә гәүдәләндерә торган художестволы образ).

**СИМВОЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — к. символизировать.

**СИМВОЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. символлаштыру, гәүдәләндерү; 2. символы булып хезмәт итү, билгесе булып тору.

**СИМВОЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— символлаштырылу, гәүдәләнделү.

**СИМВОЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — 1. *книж.* к. символика; 2. *лит. искус.* символизм (империализм чорында сәнгать һәм әдәбиятта индивидуализм һәм мистицизм белән сугарылган чиктән тыш реакцион, төшенкелеккә бирелгән юнәлеш).

**СИМВО'ЛИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— символика, символик мәгънә.

**СИМВОЛИ'СТ** *м. книж.* — символист, символизм тарафдары (язучы яки художник).

**СИМВОЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж. лит. искус.*— символистик.

**СИМВОЛИСТИ'ЧНЫЙ** *книж. лит. искус.*— к. символистический.

**СИМВОЛИ'СТКА** *ж. книж.*— к. символист.

**СИМВОЛИ'СТСКИЙ** *книж. лит. искус.*— к. символистический.

**СИМВОЛИ'ЧЕСКИ** *нареч.*— символик рәвештә.

**СИМВОЛИ'ЧЕСКИЙ** *книж. лит. искус.*— символик, символлы, символ булып тора торган.

**СИММЕТРИ'ЧЕСКИЙ**—к. симметричный.

**СИММЕТРИ'ЧНЫЙ** — симметрик, симметрияле.

**СИММЕТРИ'Я** *ж. мн.* нет — симметрия (бер бөтен нәрсәнең өлешләренең пропорциональ рәвештә урнашуы).

**СИМПАТИЗИ'РОВАТЬ** *несов.*— 1. күңелгә ошау; *симпатизирую новому знако-*

*мому* — яна танышым күңелемә ошый; 2. *книж.* теләктәшлек белдерү, теләктәшлек күрсәтү; *симпатизировать прогрессивному общественному движению* — прогрессив иҗтимагый хәрәкәткә теләктәшлек белдерү; 3. *устар. (совпадать)* туры килү, охшау, хәтерләтү.

**СИМПАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *мед.* симпатик; *симпатические боли* — симпатик авыртулар (тәннең бер өлеше авыртканда аңа симметрияле икенче өлешенең дә авырткан кебек булуы); 2. *устар.* к. симпатичный. ◇ Симпатические чернила — төссез кара (җылыга тоткач яки берәр төрле матдәгә мангач кына язуы күренә торган кара).

**СИМПАТИ'ЧНЫЙ** — 1. сөйкемле, күңелгә ягымлы; *симпатичный человек* — сөйкемле кеше; 2. *разг.* күңелгә ятырлык; күңелгә ошарлык; *симпатичная квартирка* — күңелгә ятырлык квартир.

**СИМПА'ТИЯ** *ж.* — 1. *мед.* симпатия, үзгәреш (берәр нәрсәнең үзгәрүе сәбәпле аңа якын яки симметрик булган әйбернең үзгәрүе); 2. симпатия, мәхәббәт тойгысы; 3. *перен. простореч. фам.* сөйгән кеше, яраткан кеше.

**СИМПАТЯ'ГА** *м.* и *ж. разг. фам.* — бик сөйкемле (кеше).

**СИМПРОВИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* — к. импровизировать.

**СИМПТО'М** *м. книж.* — симптом, билге, тышкы билге (берәр авыруның яки башка бер хәлнең).

**СИМПТОМА'ТИКА** *ж. мн.* нет, *мед.* — симптоматика (симптомнар турында тәгълимат).

**СИМПТОМАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *мед.* симптоматик; *симптоматическое лечение* — симптоматик дәвалау (авыруның төп сәбәпләрен түгел, бәлки аның тышкы күренешләрен генә, симптомнарын гына бетерә торган); 2. *книж.* симптомлы, симптом булып торган; *речи на конференции очень симптоматичны* — конференциядә сөйләнгән речьләр бик симптомлы.

**СИМПТОМАТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — к. симптоматика.

**СИМУЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — симулировать итү, юри... булып күренү,...-га салыну, ...-га салышу; *симулировать болезнь* — юри авыру булып күренү.

**СИМУЛЯ'НТ** *м.*, **СИМУЛЯ'НТКА** *ж.* — симулянт(ка) (алдау максаты белән булганны юк итеп, булмаганны бар итеп күрсәтүче).

**СИМУЛЯ'НТСКИЙ** — симулянт...-ы, симулянтларча...; *симулянтское поведение* — үзен симулянтларча тоту.

**СИМУЛЯ'ЦИЯ** *ж* — симуляция, симулировать итү (алдау максаты белән булганны юк итеп, булмаганны бар итеп күрсәтү).

**СИМФОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *муз.* — симфонизм (симфоник сәнгать, симфоник стиль).

**СИМФОНИ'СТ** *м. муз.* — симфонист (симфония әсәрләре язучы композитор).

**СИМФОНИ'ЧЕСКИЙ** — симфония...-ы, симфоник; *симфоническая музыка* — симфоник музыка.

**СИМФО'НИЯ** *ж.* — симфония (1. *муз.* оркестр өчен язылган зур музыкаль әсәр; 2. *перен. разг., шутл.* көчле музыка тавышы; 3. *перен.* аерым өлешләре үзара гармонияле рәвештә кушылган, берләшкән күренеш; 4. *церк., лит.* чиркәү китапларына алфавит тәртибендә төзелгән сүз күрсәткеч).

**СИНАГО'ГА** *ж.* — синагог (1. еврейләрнең гыйбадәтханәсе; 2. *устар.* еврейләрнең дини оешмасы).

**СИНАГОГА'ЛЬНЫЙ** — синагог...-ы; *синагогальное постановление* — синагог карары.

**СИНАКСА'РИЙ, СИНАКСА'РЬ** *м. церк. лит.* — к. пролог.

**СИНГАРМОНИ'ЗМ** *м. лингв.* — сингармонизм (сүз тамырындагы һәм кушымчадагы сузык авазларның үзара охшашлануы).

**СИНГАРМОНИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.* — сингармония...-ы; *сингармоническое явление* — сингармония күренеше.

**СИНДЕСМОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *анат.* — синдесмология (анатомиянең сөякләр буынтыклануын өйрәнә торган бүлеге).

**СИНДЕТИКО'Н** *м.* — синдетикон (сыек җилем).

**СИ'НДИК** *м.* — синдик (1. *истор.* борынгы Грециядә — судта яклаучы; 2. Көнбатыш Европаның кайбер илләрендә — берәр учреждениенең, общинаның яки корпорациянең эшләрен алып баручы вәкиле).

**СИНДИКАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — синдикализм (эшчеләр хәрәкәтендә марксизмга дошман булган вак буржуаз агым).

**СИНДИКАЛИ'СТ** *м.*, **СИНДИКАЛИ'СТКА** *ж.* — синдикалист(ка), синдикализм тарафдары.

**СИНДИКАЛИ'СТСКИЙ** — синдикалист...-ы, синдикалистлар...-ы; *синдикалистские профсоюзы* — синдикалистлар профсоюзлары.

**СИНДИКА'ЛЬНЫЙ** — к. синдикалистский.

**СИНДИКА'Т** *м.* — синдикат (1. империалистик илләрдә предпринимательләрнең монополистик берләшмәсе; 2. СССРда нэпның башлангыч чорында промышленностьның берәр төрле тармагында планлы рәвештә чимал сатып алу һәм трестларның продукциясен сату максаты белән оештырылган трестлар берләшмәсе; 3. кайбер буржуаз илләрдә профсоюзлар исеме).

**СИНДИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон.* — синдикатларга берләштерү.

**СИНДИЦИ'РОВАТЬСЯ** *экон.* — 1. *сов.* и *несов.* синдикатларга берләшү; 2. *несов. страд.* синдикатларга берләштерелү.

**СИНЕВА'** *ж.* — 1. *только ед.* күк төс, зәңгәрлек; *синева воды* — суның күк төсе; 2. *обл.* к. синяк 1; 3. *только ед. спец* күгәреп черү (үзагачта була).

**СИНЕВА'ТЫЙ** — күгелҗем, зәңгәрсу.

**СИНЕГЛА'ЗЫЙ** — күк күзле, зәңгәр күзле.

**СИНЕДРИО'Н** *м.* — синедрион (1. борынгы Иудеядә—старейшиналар советы; 2. *перен. шутл. устар.* җыелыш, җыен).

**СИНЕ'КДОХА** *ж. лит.* — синекдоха (га

дәттә шигъри сөйләмдә һәм ораторлар речендә стилистик алымнарның берсе).

**СИНЕКУ'РА** *ж. книж.* — синекура (зур доход бирә, ләкин хезмәт куюны таләп итми торган вазифа).

**СИНЕ'ЛЕВЫЙ** *спец.* — к. синельный.

**СИНЕ'ЛЬ** I *ж. чаще собир.* — синель (чук ясау, чигү өчен китә торган бәрхет яки йөнтәс шнур).

**СИНЕ'ЛЬ** II *ж. мн.* нет, *обл.* — к. сирень.

**СИНЕ'ЛЬКА** I *ж. чаще собир. спец.* — к. синель I.

**СИНЕ'ЛЬКА** II *ж. обл.* — 1. к. синель II; 2. *бот. (цветок колокольчик)* кыңгырау чәчәк.

**СИНЕМАТО'ГРАФ** *м.* — к. кинематограф.

**СИНЁНЫЙ** *разг.* — синькага манылган, синькаланган.

**СИ'НЕНЬКАЯ** *ж. в знач. сущ. просторечн. устар.* — биш сумлык кәгазь акча.

**СИНЕРО'Д** *м. мн.* нет, *хим.* — к. циан.

**СИНЕРО'ДИСТЫЙ, СИНЕРО'ДНЫЙ** *хим.* — к. цианистый.

**СИНЕ'ТЬ** *несов.* — 1. зәңгәрләнеп күренү; *во ржи синеют васильки* — арыш арасында күкчәчәкләр зәңгәрләнеп күренә; 2. күгәрү; *руки синеют от холода* — суыктан куллар күгәрә.

**СИ'НИЙ** — күк, күк төс; зәңгәр, зәңгәр төс. ◇ **Ни синь пороха** — к. порох. **Синий мундир** *перен. разг. дореvол.* — жандарм.

**СИНИ'ЛЬНЫЙ** *спец., обл.*—синькалау...-ы, синькалый торган; *синильный чан* — (кер) синькалый торган чан.

**СИНИ'ТЬ** *несов.*—1. күк (зәңгәр)төскә буяу, күк (зәңгәр) төскә кертү; 2. синькалау, синькага ману; *синить бельё* —керне синькалау.

**СИНИ'ЦА** *ж.* — 1. песнәк; 2. *просторечн. фам.* к. синенькая.

**СИНКЛИ'Т** *м.*—синклит (1. *истор.* борынгы Грециядә — иң эре түрәләр җыелышы; 2. *перен. шутл.* җыелыш, җыен, төркем).

**СИНКО'ПА** *ж. лингв.*— синкопа (сүз уртасындагы авазның төшеп калуы).

**СИНКОПИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. лингв.*— (сүз уртасындагы) авазны төшереп калдыру.

**СИНКОПИ'РОВАТЬСЯ** *лингв.* — 1. *сов.* и *несов.* (сүз уртасында) аваз төшеп калу; 2. *несов. страд.* төшереп калдырылу (аваз турында).

**СИНКРЕТИ'ЗМ** *м. книж.* — синкретизм (1. *науч.* берәр күренешнең башлангыч чорында мөстәкыйль рәтләргә бүленмәгәнлеге; 2. *филос.* философия һәм диннәр тарихында — эклектизмның бер төре).

**СИНКРЕТИ'СТ** *м. книж.* — синкретист, синкретизм тарафдары.

**СИНКРЕТИ'ЧЕСКИЙ** *науч. филос.* — синкретизм...-ы, синкретик; *синкретическая философия* — синкретизм философиясе.

**СИНОВИА'ЛЬНЫЙ** *анат.* — синовиаль...; *синовиальная жидкость*—синовиаль сыекча (буын сыекчасы).

**СИНО'ВИЯ** *ж. мн.* нет, *анат.* — синовия (буын бөгелешләрендә була торган үтә күренмәле җилемсыман сыекча).

**СИНО'Д** *м.* — синод (1917 елга кадәр Россиядә югары чиркәү учреждениесе).

**СИНОДА'ЛЬНЫЙ** *офиц. церк.* — синод...-ы; *синодальное здание* — синод бинасы.

**СИНО'ДИК** *м. церк.* — синодик (чиркәүләрдә гыйбадәт кылу вакытында үлгән кешеләрне искә алу өчен төзелгән исемлек).

**СИНО'ДСКИЙ** *устар.* — синод...-ы; *синодский чиновник* — синод чиновнигы (синодта хезмәт итүче чиновник).

**СИНО'ЛОГ** *м. спец.* — синолог, китаист (кытай теле, әдәбияты, тарихы, культурасы белгече).

**СИНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — синологик, китаистика буенча...-ган; *синологические исследования* — синологик тикшеренүләр.

**СИНОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — синология, китаистика (Кытайны, кытай телен һәм әдәбиятын өйрәнә торган фәннәрнең җыелмасы).

**СИНО'НИМ** *м. лингв.* — синоним (аваз-лар составы ягыннан аерыла, ләкин мәгънәсе ягыннан бик якын яисә тәңгәл килә торган сүз; мәсәлән, *өй, йорт, ызба,* сүзләре яки *нечкә, нәзек* сүзләре һ. б.).

**СИНОНИ'МИКА** *ж. мн.* нет, *лингв.* — синонимика (1. лексикологиянең синонимнарны, ягъни мәгънәдәш сүзләрне өйрәнә торган бүлеге; 2. теге яки бу телнең синонимнар системасы).

**СИНОНИМИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.*—синоним..., синоним...-ы, синонимик; *синонимическое слово* — синоним сүз.

**СИНОНИМИ'ЧНЫЙ** *лингв.* — к. синонимический.

**СИНОНИ'МИ'Я** *ж.*—синонимия (1. *лингв.* сүзләрнең авазлар составы ягыннан башка булып та, мәгънәләре ягыннан бер яки якын булуы; 2. *лит.* ораторлар сөйләмендә— синонимнарны беррәттән яки бер-берсенә бик якын куллану).

**СИНО'ПСИС** *м. филол.* — синопсис (бер үк мәсьәләгә кагылган материаллар, мәкаләләр җыентыгы).

**СИНО'ПТИК** *м. спец.*—синоптик (синоптик карталар төзүче белгеч-метеоролог).

**СИНО'ПТИКА** *ж. мн.* нет, *спец. метеор.*— синоптика (синоптик карталар төзү).

**СИНОПТИ'ЧЕСКИЙ** *спец. метеор.* — синоптик; *синоптическая карта*—синоптик карта (һава торышын чагылдырган географик карта).

**СИНТА'ГМА** *ж. лингв.*— синтагма (билгеләүче һәм билгеләнә торган элементлардан гыйбарәт булган сүзләрнең яки сүз кисәкләренең тезмәсе).

**СИ'НТАКСИС** *м. мн.* нет, *лингв.* — синтаксис (грамматиканың җөмләләрне, сүз тезмәләрен өйрәнә торган бүлеге).

**СИНТАКСИ'ЧЕСКИЙ, СИНТАКТИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.* — синтаксик.

**СИ'НТЕЗ** *м. мн.* нет — синтез (1. *науч. филос.* анализ процессында барлыкка килгән аерым элементлар арасындагы бәйләнешне билгеләүдән һәм аларны бер бөтенгә кушудан гыйбарәт тикшеренү методы; 2. Гегельнең идеалистик диалектикасында—

берәр төрле күренешнен үсешендә үзеннән элекке булган баскычларны берләштерә һәм аларның каршылыкларын чишә торган яңа бер баскыч; 3. *хим.* химик реакция ярдәмендә аерым элементлардан яңа бер химик кушылма ясау).

**СИНТЕЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — синтезлау.

**СИНТЕЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — синтезлану.

**СИНТЕ'ТИК** *м. книж.* — синтетик (синтезлауга сәләтле яки синтезларга яратучы кеше).

**СИНТЕ'ТИКА** *ж. мн.* нет, *науч. филос.* — синтетика (синтезга китерә торган фикер йөртү, тикшеренү методы).

**СИНТЕТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. синтетик; ***синтетический метод*** — синтетик метод; 2. синтетик, синтезга нигезләнгән; ***синтетическое суждение*** — синтезга нигезләнгән фикер йөртү; 3. синтезлауга сәләтле; ***синтетический ум*** — синтезлауга сәләтле акыл; 4. *хим. тех.* синтетик, ясалма; ***синтетический каучук*** — синтетик каучук, ясалма каучук.

**СИ'НУС** I *м. мат.* — синус (почмакның тригонометрик функциясе).

**СИ'НУС** II *м. анат.* — синус (организмдагы төрле чокырчыклар, куышлыклар, ябык каналлар һ. б.).

**СИНХРОНИЗА'ТОР** *м. тех.* — синхронизатор (теге яки бу процессларны, хәрәкәтләрне бер үк вакытта булдыру өчен хезмәт итә торган җайланма).

**СИНХРОНИЗАЦИО'ННЫЙ** *тех.* — синхронизация...-ы, синхронизацион; ***синхронизационная техника*** — синхронизацион техника.

**СИНХРОНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов., науч. тех.* — синхронлаштыру, бер үк вакытта булдыру.

**СИНХРОНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд., науч. тех.* — синхронлаштырылу, бер үк вакытта булдырылу.

**СИНХРОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *науч. тех.* — синхронизм, бер үк вакытта булу (берәр төрле процессларның, хәрәкәтләрнең бер үк вакытка туры килүе һәм үзара бәйләнештә булуы).

**СИНХРОНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *науч.* — к. синхронический.

**СИНХРОНИ'ЧЕСКИЙ** *науч.* — синхронизм...-ы, синхроник; ***синхронический метод*** — синхроник метод.

**СИНХРОНИ'Я** *ж. мн.* нет, *науч.* — 1. к. синхронизм; 2. синхрония (тел үсешендә тел күренешләренең теләсә нинди моментта үзара бәйләнеше һәм бер-берсенә буйсынуы).

**СИНХРО'ННЫЙ** *науч. тех.* — синхрон; ***синхронные механизмы*** — синхрон механизмнар.

**СИНЬ** *ж. мн.* нет—1. к. синева 1; 2. *живоп. спец. устар.* *(синяя краска)* күк (зәңгәр) буяу; 3. *горн.* күк (зәңгәр) төстәге руда.

**СИ'НЬКА** *ж.* — 1. к. синить; 2. синька (а. ак кергәрне мана торган зәңгәр буяу; б. *спец.* махсус копировка кәгазе).

**СИНЬО'Р** *м.* — синьор (Италиядә—ирләр исеменә кушып яки аларга мөрәҗәгать иткәндә әфәнде мәгънәсендә әйтелә торган сүз).

**СИНЬО'РА** *ж.* — синьора (Италиядә — хатыннар исеменә кушып яки аларга мөрәҗәгать иткәндә ханым мәгънәсендә әйтелә торган сүз).

**СИНЬОРИ'НА** *ж.* — синьорина (Италиядә — кызларның исеменә кушып яки аларга мөрәҗәгать иткәндә туташ мәгънәсендә әйтелә торган сүз).

**СИНЮ'ХА** *ж.*—1. *бот.* күкчәчәк; 2. *обл.* *(сыроежка)* ал гөмбә; 3. *мед.* тире(нең) күгәрүе (йөрәк авырулы кешеләрдә була); 4. *простореч. обл. устар.* к. синенькая.

**СИНЯ'К** *м.* — 1. (тәндә) күгәргән урын; 2. *охот., обл.* яшь ак төлке.

**СИП** *м. разг.* — 1. *(сипота)* карлыгу; 2. *(сиплый звук)* карлыккан тавыш; сызгырган тавыш.

**СИПЕ'ЛКА** *ж. обл.* — сыбызгы.

**СИПЕ'ТЬ** *несов.* — 1. гырылдау, гырлау, сызгырган тавышлар чыгару; ***сипеть во сне*** — йоклаганда гырылдау; 2. *разг.* карлыккан тавыш белән сөйләү; 3. *перен. простореч. фам.* (ачулы тавыш белән) пышылдап сөйләү, пышылдау; ***не сипи на меня*** — пышылдама миңа; 4. *чаще безл. разг.* карлыгу; ***в горле у меня сипит*** — тамагым карлыккан. ◇ **Самовар сипит** — самовар җырлый, самовар сызгыра.

**СИ'ПЛОСТЬ** *ж.* — карлыкканлык, карлыккан булу.

**СИ'ПЛЫЙ** — карлыккан.

**СИ'ПНУТЬ** *несов. разг.* — карлыгу.

**СИПОВА'ТЫЙ** — бераз карлыккан.

**СИПО'ВКА** *ж. обл.* — сыбызгы.

**СИПОТА'** *ж. мн.* нет — 1. карлыгу; 2. карлыккан тавыш; ***говорить с сипотой*** — карлыккан тавыш белән сөйләү.

**СИРЕ'НА** *ж.* — сирена (1. грек мифологиясендә — хатын-кыз башлы, кош гәүдәле диңгездә яшәүче мифик зат; 2. *перен. книж. устар.* сөйкемле, чибәр, ләкин явыз хатын; 3. *зоол.* җир-су хайваны; 4. *разг.* төрле югарылыктагы тавышлар чыгару һәм тавыш тирбәлешләрен үлчәү приборы; 5. сигнал гудогы, мәсәлән, пароходларда).

**СИРЕ'НЕВЫЙ** — 1. сирень...-ы; ***сиреневый куст*** — сирень куагы; 2. сирень төсле, канәфер чәчәге төсле, ачык шәмәхә төстәге; ***сиреневое платье*** — ачык шәмәхә төстәге күлмәк.

**СИРЕ'НЬ** *ж. мн.* нет—сирень (куагы һәм чәчәге), канәфер чәчәге, канәфер агачы.

**СИ'РЕЧЬ** *союзная частица, старин., теперь ирон.* — ягъни, икенче төрле әйткәндә, атап әйткәндә.

**СИ'РИН** *м.* — сирин (1. борынгы рус язмаларында һәм хикәяләрендә — башы һәм күкрәге хатын-кыз башына һәм күкрәгенә охшаган мифик кош; 2. *зоол.* ябалаклар семьялыгыннан кечкенә бер кош).

**СИРО'ККО** *м. нескл.* — сирокко (Төньяк

Африкада һәм Көньяк Европада коры эссе жил).

**СИРО'П** *м.* — сироп, куе ширбәт.

**СИ'РОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. ятимлек, үксезлек; 2. ялгызлык, бәхетсезлек.

**СИРОТА'** *ж.* — ятим, үксез (бала).

**СИРОТЕ'ТЬ** *несов.* — 1. ятим, калу; 2. *обл.* ятим тору, ятим яшәү; *дети уж восьмой год сиротеют* — балалар сигезенче ел ятим яшиләр инде; 3. *перен.* якын кешене югалту, сөекле кешене югалту; 4. *перен.* бушап калу, ятим калу; *уезжают дети — сиротеет дом* — балалар китә — өй ятим кала.

**СИРОТИ'НА** и **СИРОТИ'НКА** *м.* и *ж. разг.* — к. сирота.

**СИРОТИ'ТЬ** *несов.* — ятим калдыру.

**СИРОТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. боеклык, төшенкелек, ятимнәрчә булу; 2. ялгызлык.

**СИРОТЛИ'ВЫЙ** — 1. боек, төшенке, күңелсез, ятимсыман, ятимнәрчә...; *сиротливый вид* — боек кыяфәт; 2. *(одинокий)* ялгыз.

**СИРО'ТСКИЙ** — ятим...-ы, ятимнәр...-ы, үксез...-ы, үксезләр...-ы; *сиротская доля* — ятимнәр язмышы; *сиротская зима (разг.)* — ятимнәр кышы (жылы кыш).

**СИРО'ТСТВО** *ср. мн.* нет — 1. ятимлек, үксезлек; 2. *перен. (одиночество)* ялгызлык.

**СИРО'ТСТВОВАТЬ** *несов.* — к. сиротеть 2.

**СИ'РЫЙ** *книж.* — 1. *устар. (лишившийся родителей)* ятим, үксез; 2. *перен.* ялгыз, бәхетсез.

**СИСТЕ'МА** *ж.* — система, тәртип.

**СИСТЕМАТИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. систематизировать.

**СИСТЕМАТИЗИ'РОВАТЬ** *сов. книж.* — системалаштыру, системага салу, тәртипкә салу.

**СИСТЕМАТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *книж.* — 1. *сов.* и *несов.* системалашу, системага салыну, тәртипкә салыну; 2. *несов. страд.* системалаштырылу, системага салыну, тәртипкә салыну.

**СИСТЕМА'ТИК** *м. спец.* — систематик (систематика белгече).

**СИСТЕМА'ТИКА** *ж. науч.* — систематика (1. *только ед.* предметларны һәм күренешләрне системага салу, классификацияләү, төркемләү; 2. ботаникада һәм зоологиядә үсемлекләрне һәм хайваннарны классификацияләү, төркемләү бүлеге).

**СИСТЕМАТИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — системалы рәвештә.

**СИСТЕМАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *книж.* системалы, системалы рәвештә...; *систематическое изложение фактов* — фактларны системалы рәвештә бәян итү; 2. *(не прекращающийся)* бертуктаусыз, өзлексез, системалы рәвештә...; 3. *биол.* систематика...-ы, систематик; *систематические категории* — систематик категорияләр.

**СИСТЕМАТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — системалы рәвештә булу, системалылык, тәртиплелек, эзлеклелек.

**СИСТЕМАТИ'ЧНЫЙ** — 1. к. систематический 1, 2; 2. тәртип яратучан, тәртипле, эзлекле; *он человек систематичный* — ул тәртип яратучан кеше.

**СИ'СТОЛА** *ж. мн.* нет, *физиол.* — систола (йөрәк мускулының ритмик рәвештә кыскаруы).

**СИ'СЬКА, СИ'СЯ** *ж. обл. просторен.* — 1. к. сосок 1; 2. ими, имчәк.

**СИ'ТЕЦ** *м.* — 1. *(ткань)* ситсы; 2. *редко (платье из ситца)* ситсы күлмәк.

**СИ'ТНИК I** *м. разг.* — к. ситный 3.

**СИ'ТНИК II** *м. бот.* — куга (болын үләне).

**СИ'ТНЫЙ** — 1. кыл иләктән иләнгән; *ситная мука* — кыл иләктән иләнгән он; 2. кыл иләктән иләнгән оннан пешерелгән; *ситный хлеб* — кыл иләктән иләнгән оннан пешерелгән ипи; 3. *в знач. сущ.* кыл иләктән иләнгән оннан пешерелгән ипи.

**СИ'ТО** *ср.* — кыл иләк, еш иләк.

**СИТУАЦИО'ННЫЙ** *геодез.* — ситуацион, рельеф төшерелгән (планда яки картада рельефны чагылдыра торган); *ситуационный план* — ситуацион план.

**СИТУА'ЦИЯ** *ж.* — 1. ситуация, хәл, обстановка; 2. *геодез.* ситуация (рельефны: тауларны, елгаларны, урманнарны картада яки планда күрсәтү).

**СИ'ТЦЕВЫЙ** — ситсы...; ситсыдан тегелгән; *ситцевое платье* — ситсы күлмәк.

**СИТЦЕКРАСИ'ЛЬНЫЙ** *тех.* — ситсы буяу...-ы; *ситцекрасильная мастерская* — ситсы буяу мастерское.

**СИТЦЕНАБИВНО'Й** *тех.* — ситсы бизәкли торган.

**СИТЦЕПЕЧА'ТАНИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.* — ситсы бизәкләү (махсус машина ярдәмендә).

**СИ'ТЧИК** *м. просторен.* — к. ситец.

**СИФИЛИДО'ЛОГ** *м. спец.* — сифилидолог (сифилис авыруын дәвалаучы врач; сифилидология белгече).

**СИФИЛИДОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — сифилидология (медицинада — сифилис авыруын һәм аның белән көрәш алып бару юлларын өйрәнә торган бүлек).

**СИФИЛИ'ДЫ** *мн. мед.* — сифилидлар (сифилис бетчәләре).

**СИ'ФИЛИС** *м. мн.* нет, *мед.* — сифилис (венерик авыру).

**СИФИЛИ'ТИК** *м.*, **СИФИЛИТИ'ЧКА** *ж.* — сифилитик, сифилис белән авыручы.

**СИФО'Н** *м.* — сифон (1. *физ.* сыекчаларны бер савыттан икенче савытка бушату өчен хезмәт итә торган кәкре көпшә; 2. шундый көпшәле шешә, савыт; 3. *зоол.* кайбер моллюскларда — көпшәсыман орган; 4. *тех.* паровоз мичендә һава тарту көчен арттыра торган махсус прибор).

**СИФО'ННЫЙ** *физ. тех.* — сифон..., сифонсыман, сифонлы; *сифонная трубка* — сифон көпшә.

**СИЯ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. якты(лык); *лунное сияние* — ай яктысы; 2. *(блеск)* ялтырау; 3. балку, балкыш; *небесный свод поголубел и вновь подёрнулся сиянием* (Пушкин) — күк йөзе зәңгәрләнде дә яңадан балкыды; *северное сияние* — төньяк балкышы; 4. нур, нурлар бәжрасы; *далеко,*

*там, луна в сиянии восходит* (Пушкин) — анда, еракта, ай нурлар эчендә калка. ◇ **В сиянии славы** — даны чәчәк атканда.

**СИЯ'ТЕЛЬСТВО** *ср. офиц. дореBол.* — сиятельство (князьләргә, графларга һәм аларның хатыннарына, балаларына эндәшкәндә әйтелә торган сүз).

**СИЯ'ТЬ** *несов.* — 1. нур чәчү; балку, балкып тору; 2. ялтырау, ялтырап тору.

**СКАБИО'ЗА** *ж. бот.* — яламча (үсемлек).

**СКАБРЁЗНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* оятсызлык, әдәпсезлек; 2. *(скабрёзное слово)* оятсыз сүз.

**СКАБРЁЗНЫЙ** — оятсыз, әдәпсез, килешсез.

**СКАЗ** *м. лит.* — сөйләк (күбесенчә телдән, гадәттә беренче заттан, сөйләнә торган хикәя). ◇ **Вот тебе и весь** (или **последний мой**) **сказ** *разг.* — менә минем сиңа актык сүзем шул (артык бернәрсә дә сиңа әйтәсем юк).

**СКАЗА'НИЕ** *ср. книж. лит.* — хикәя (борынгылардан күчә килгән хикәя).

**СКА'ЗАННЫЙ** — әйтелгән. ◇ **Сказано — сделано** — әйтте — бетте (күп сөйләп торырга яратмый(м)).

**СКАЗАНУ'ТЬ** *сов. простореч. фам. шутл.* — әйтеп салу, әйтеп ташлау.

**СКАЗА'ТЕЛЬ** *м.* — 1. *старин.* хикәяләр сөйләүче; 2. *обл.* к. сказитель.

**СКАЗА'ТЬ** *сов.* — 1. әйтү, дию, дип әйтү; *ты скажи им...* — син аларга әйт...; 2. *устар. (рассказать)* сөйләү; 3. *старин. (приказать)* боеру, боерык бирү, кушу. ◇ **Скажи(те)!** — кара(гыз) әле! **Да и то сказать** или **и то сказать** — к. тот. **К примеру сказать** *разг.* — мәсәлән, әйтик. **К слову сказать** — сүз уңаенда әйткәндә. **Как сказать** *разг.* — ничек дип әйтергә соң; алай ук дип әйтеп булмый. **Кстати сказать** — сүз уңаенда әйткәндә. **Нельзя сказать, чтобы... (что...)** — ... дип әйтеп булмый, ...дип әйтмәс идем. **Нечего сказать** *разг. ирон.* — чынлап та, чыннан да, дөрестән дә. **По правде сказать** или **правду сказать** — дөресен генә әйткәндә. **С позволения сказать** — к. позволение. **Так сказать** или **можно сказать** — дип әйтергә мөмкин. **Чтобы не сказать** *эвф.* — дөресрәген әйткәндә. **Чтобы не сказать больше** *эвф.* — йомшартып кына әйткәндә, йомшак кына итеп әйткәндә. **Шутка(ли) сказать** — к. шутка.

**СКАЗА'ТЬСЯ** *сов.* — 1 *разг.* әйтү, белдерү; *ушёл, не сказавшись* — әйтмичә киткән; 2. үзен... белдерү, үзен... дип әйттерү; *сказался дома* — үзен өйдә дип әйттергән; 3. *разг. устар.* к. назваться 1; 4. беленү, күренү, сизелү, чагылу; *в его работе сказалась хорошая подготовка* — аның эшеннән (эшенә карап әйткәндә) яхшы хәзерлекле булуы сизелде; 5. *разг.* әйтелү; *хорошая фраза сказалась* — яхшы җөмлә әйтелде.

**СКАЗИ'ТЕЛЬ** *м.*, **СКАЗИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. обл. этногр.* — әкиятче, бәетче.

**СКА'ЗКА** *ж.* — 1. әкият; 2. *истор. (список, реестр)* исемлек; 3. *офиц. старин. (официальное показание)* күрсәтү, сөйләү. ◇ **Сказка про белого бычка** *шутл. погов.* — бер балык башын чәйнәү (һаман бернәрсәне кабатлап сөйләү).

**СКА'ЗОВЫЙ** *лит.* — сөйләк...-ы; *сказовый стиль* — сөйләк стиле.

**СКА'ЗОЧНИК** *м.*, **СКА'ЗОЧНИЦА** *ж.* — әкиятче, әкиятләр сөйләүче.

**СКА'ЗОЧНЫЙ** — 1. әкият...-ы; *сказочный сюжет* — әкият сюжеты; 2. әкияттәге, әкияттә генә була торган; *сказочный богатырь* — әкияттә генә була торган баһадир; 3. *перен.* әкияттәге, искиткеч зур, гаҗәп зур, ышанмаслык зур; *сказочное богатство* — искиткеч зур байлык.

**СКАЗУ'ЕМОЕ** *ср. грам.* — хәбәр.

**СКАЗУ'ЕМОСТНЫЙ** *лингв.* — хәбәрлек...-ы; *сказуемостное значение* — хәбәрлек мәгънәсе.

**СКАЗУ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *лингв.* — хәбәрлек.

**СКА'ЗЫВАТЬ** *несов. простореч. устар.* — сөйләү.

**СКА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. сказаться; 2. *страд. обл. нар.-поэт.* — сөйләнү.

**СКАКА'ЛКА** *ж.* — сикергеч (уенчык).

**СКАКА'ЛЬНЫЙ** *анат. спец.* — к. скакательный.

**СКАКА'ТЕЛЬНЫЙ** *анат. спец.* — сикерү...-ы; *скакательный сустав* — сикерү буыны (атларга карата).

**СКАКА'ТЬ** *несов.* — 1. сикерү, сикереп бару, сикерә-сикерә бару (килү); *лягушка скачет* — бака сикерә; 2. сикертеп чабу, сикертеп чаптырып килү (бару); *всадник скачет* — җайдак чаптырып килә; 3. *спорт.* чабу, чабышта катнашу (ат чабышында катнашу); 4. *перен. разг. фам.* сикерү (бию мәгънәсендә); *скакать на балах* — балларда сикерү.

**СКАКНУ'ТЬ** *однокр. разг.* — сикереп кую.

**СКАКОВО'Й** — чапкын, чабыш...-ы, йөгерек; *скаковая лошадь* — чабыш аты. ◇ **Скаковое общество** — ат чабышлары оештыра торган җәмгыять. **Скаковая конюшня** — чабыш атлары араны. **Скаковая дорожка** — ат чабышлары үткәрелә торган юл. **Скаковой жокей** — чабыш атлары жокее. **Скаковой приз** — ат чабышында алынган (бирелә торган) приз.

**СКАКУ'Н** *м.* — 1. чабыш аты, чапкын ат, йөгерек ат; 2. *разг. фам. (непоседа)* тиктормас, кыбырсык; 3. *зоол.* сикергәк коңгыз; 4. *зоол.* (диңгезнең комлы яры буйларында таш асларында яшәүче) кысласыман хайван; 5. *обл.* к. кузнечик; 6. *охот.* (кеше күгәрченнәрен нәртергә өйрәтелгән) күгәрчен.

**СКАКУНО'К** *м.* — 1. к. скакун; 2. сикерә торган уенчык, сикергеч уенчык.

**СКАКУ'НЧИК** *м. зоол.* — (табышын сикереп тота торган) үрмәкүч.

**СКАКУ'НЬЯ** *ж. разг. фам.* — к. скакун 2.

**СКАКУ'ХА** *ж. обл.* — к. лягушка.

**СКАЛ** *м. тех* — к. скадка 2.

**СКА'ЛА** *ж.*—1. *устар.* к. шкала; 2. *муз.* скала, музыкаль гамма.
**СКАЛА'** *ж.*— кыя, кыя таш.
**СКАЛАМБУ'РИТЬ** *сов. разг.*— каламбур әйтеп (язып) ташлау.
**СКАЛДЫ'РНИК** *м. обл. презрит.*—к. скаред.
**СКАЛДЫ'РНИЧАТЬ** *нёсов. обл. презрит.*— к. скаредничать.
**СКАЛДЫ'РНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *обл. презрит.*— к. скаредность.
**СКАЛИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет — кыя ташлы булу, кыялы булу.
**СКАЛИ'СТЫЙ** — кыя ташлы, кыялы.
**СКА'ЛИТЬ** *несов.*: **скалить зубы** — тешләрне ыржайту.
**СКА'ЛИТЬСЯ** *несов.*— тешләрне ыржайту; авызны еру.
**СКА'ЛКА** *ж.*—1. уклау; 2. *тех. (в ткацком станке)* боргыч таяк.
**СКА'ЛО** *ср. обл.*— к. скалка 2.
**СКАЛОЗУ'Б** *м. разг. устар.*— к. зубоскал.
**СКАЛОЗУ'БСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. устар.*— к. зубоскалить.
**СКА'ЛЫВАЛЬЩИК** *м. спец.*— ватучы, чабучы (мәсәлән, боз чабучы).
**СКА'ЛЫВАТЬ** *несов.*— к. сколоть.
**СКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.*—1. *разг.* к. сколоться; 2. *страд.* чабылу, ватылу, китеп алыну.
**СКАЛЬД** *м.*— скальд (борынгы Скандинавиядә — җырчы-шагыйрь).
**СКАЛЬКИ'РОВАТЬ** *сов. спец.*— к. калькировать.
**СКАЛЬКУЛИ'РОВАТЬ** *сов. торг.*— к. калькулировать.
**СКА'ЛЬНЫЙ** *спец.*—1. кыя ташлы; *скальный грунт* — кыя ташлы грунт; 2. кыя ташлы грунтта алып барыла торган; *скальные работы* — кыя ташлы грунтта алып барыла торган эшләр.
**СКАЛЬП** *м.*— скальп (чәче белән бергә баштан тунап алынган баш тиресе).
**СКА'ЛЬПЕЛЬ** *м. мед.*— скальпель (хирургиядә кулланыла торган кечкенә пычак).
**СКАЛЬПИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— баш тиресен тунап алу.
**СКА'ЛЬЩИК** *м. спец.*— кыя ташчы (эшче).
**СКАМЕ'ЕЧНЫЙ** — скамья...-ы; *скамеечная доска* — скамья тактасы.
**СКАМЕ'ЙКА** *ж.*— кечкенә скамья, скамья.
**СКАМЬЯ'** *ж. книж.*— скамья. ◇ **Попасть (или сесть) на скамью подсудимых** — судка эләгү. **Со школьной скамьи** — мәктәп скамьясыннан чыккач та, мәктәпне бетергәч тә. **На школьной скамье** — мәктәп скамьясында, мәктәптә укыганда.
**СКАНДА'Л** *м.*— 1. гауга, җәнҗал, скандал; *подняли скандал* —гауга чыгардылар; 2. *разг. фам.* юньсезлек, мәгънәсезлек; *какой скандал, я забыл написать письмо!*— нинди мәгънәсезлек (бу), хат язарга онытканмын!
**СКАНДАЛЁЗНЫЙ** *разг. устар.* — к. скандальный .1
**СКАНДАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— уңайсыз хәлдә калдыру, хур итү.
**СКАНДАЛИ'СТ** *м.*, **СКАНДАЛИ'СТКА** *ж.*— җәнҗалчы, гаугачы.
**СКАНДА'ЛИТЬ** *несов.*— 1. җәнҗал чыгару, гауга куптару, тавыш чыгару; *здесь нельзя скандалить* — монда җәнҗал чыгарырга ярамый; 2. *разг.* уңайсыз хәлгә кую, хурлыкка төшерү; *пожалуйста, не скандаль меня* — зинһар, мине хур итмә!
**СКАНДА'ЛИТЬСЯ** *несов. разг.*— уңайсыз хәлгә төшү, хур булу.
**СКАНДА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — хурлыклылык.
**СКАНДА'ЛЬНЫЙ** — 1. хурлыклы, гаугалы; *скандальный случай* — хурлыклы вакыйга; 2. *разг. фам.* бик авыр; *у меня скандальное положение с деньгами* — минем акча мәсьәләсе бик авыр; 3. *разг.* гаугачыл, җәнҗал чыгарырга яратучан; *скандальный человек* — гаугачыл кеше.
**СКА'НДИЕВЫЙ** *хим.*— скандий...-ы; *скандиевые соединения* — скандий кушылмалары.
**СКА'НДИЙ** *м. мн.* нет, *хим.*— скандий (химик элемент).
**СКАНДИНА'ВСКИЙ** — Скандинавия...-ы; *скандинавские языки* — Скандинавия телләре.
**СКАНДИНА'ВЦЫ, СКАНДИНА'ВЫ** *мн.*— Скандинавия халыклары, скандинавиялеләр.
**СКАНДИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— ижекләп кычкырып әйтү, өзеп-өзеп кычкырып әйтү; өзеп-өзеп уку.
**СКАНДИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— өзеп-өзеп әйтелү, өзеп-өзеп укылу.
**СКАНДОВА'ТЬ** *несов.*— к. скандировать.
**СКАНДОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— к. скандироваться.
**СКА'НЕЦ** *м. обл.*— тәбикмәк.
**СКА'НЫЙ** *обл.*— к. филигранный 1.
**СКАНЬ** *ж. мн.* нет, *обл.*— к. сканье 2.
**СКАНЬЕ, СКАНЬЁ** *ср. мн.* нет, *обл.*— 1. к. скать; 2. *собир.* каткан җеп, бөтерелгән җеп; 3. к. филигран.
**СКА'ПАТЬ** *сов. простореч.*— тамызып бетерү.
**СКА'ПЛИВАТЬ** *несов.*— к. скопить 1.
**СКА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.*—1. җыелу, туплану; 2. *страд.* җыелу, тупланылу.
**СКАПОЛИ'Т** *м. мин.*— скаполит (минерал).
**СКАПОТИ'РОВАТЬ** *сов. ав.* — утырганда борыны белән төртелү (самолёт турында).
**СКАПУ'СТИТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. скапутиться.
**СКАПУ'ТИТЬ** *сов. простореч.*— башына җитү, башын ашау; юкка чыгару, һәлак итү, бетерү, юк итү.
**СКАПУ'ТИТЬСЯ** *сов. простореч.*— һәлак булу, үлү, юкка чыгу, бетү, юк булу.
**СКА'ПЫВАТЬ** I *несов. простореч.*— к. скапать.
**СКА'ПЫВАТЬ** II *несов.*—к. скопать.
**СКА'ПЫВАТЬСЯ** I *несов. страд. простореч.*— тамызып бетерелү.

**СКА'ПЫВАТЬСЯ** II *несов. страд.*— казып ташлану.

**СКАРАБЕ'Й** *м.*— скарабей (1. *зоол.* көньякта яши торган тирес коңгызы; 2. *истор.* борынгы мисырлыларда — изге коңгызның акчага һәм ташка төшерелгән рәсеме яки балчыктан ясап ялтыратылган кечкенә сыны).

**СКАРБ** *м. мн.* нет, *разг.*— өй әйберләре, өй кирәк-яраклары, өй эчендәге кирәк-яраклар, вак-төяк әйберләр.

**СКА'РБНИК** *м. истор.*— казначы (элек заман Украинада).

**СКА'РБНИЦА** *ж. истор.*— казна (элек заман Украинада).

**СКА'РБНИЧИЙ** *м. истор.*— к. скарбник.

**СКА'РБОВЫЙ** *истор.*— казна...-ы; *скарбовая канцелярия украинского гетмана* — Украина ґетманының казна канцеляриясе.

**СКА'РЕД** *м.*, **СКА'РЕДА** *м.* и *ж. простореч. бран.*— саран кеше, комсыз кеше, карун.

**СКА'РЕДНИК** *м. обл.*— к. скаред.

**СКА'РЕДНИЦА** *ж. обл.*— к. скаред.

**СКА'РЕДНИЧАТЬ** *несов. простореч.*— саранлану, саранлык күрсәтү, комсызлану.

**СКА'РЕДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *просторeч.*— саранлык, карунлык; комсызлык.

**СКА'РЕДНЫЙ** *просторeч.*— саран, карун, комсыз.

**СКАРЛАТИ'НА** *ж. мн.* нет — скарлатина (балаларда була торган йогышлы авыру).

**СКАРЛАТИ'ННЫЙ** — скарлатинадан..., скарлатинага каршы ясала торган; *скарлатинная прививка* — скарлатинадан укол.

**СКАРЛАТИНО'ЗНЫЙ** — 1. скарлатина белән авыручы; *скарлатинозный ребёнок* — скарлатина белән авыручы бала; 2. скарлатина белән авыручылар...-ы; *скарлатинозная палата* — скарлатина белән авыручылар палатасы.

**СКА'РМЛИВАТЬ** *несов.*— к. скормить.

**СКА'РМЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— ашатып бетерелү.

**СКАТ** I *м.*—1. сөзәклек; 2. *только ед. просторeч.* к. скатить I. ◇ **Скат крыши** — өй кыегы.

**СКАТ** II *м. спец.*— скат (арба яки вагонның 4 тәгәрмәче).

**СКАТ** III *зоол.*— скат (дингез балыгы).

**СКАТА'ТЬ** *сов.*—1. (түгәрәкләп) төрү; (трубкасыман итеп) чорнау; *скатать рукопись в трубку* — кульязманы түгәрәкләп төрү; 2. әвәләү, әвәләп ясау; *скатать шарик из воска* — балавыздан шарчык әвәләп ясау; 3. *обл.* басу; *скатать валенки* — киез итек басу; 4. *просторeч. фам.* (тиз генә) барып кайту, йөгереп барып кайту; 5. *школьн. арго* күчереп язып алу; *скатал диктовку у товарища* — диктовканы иптәшеннән күчереп алган.

**СКАТА'ТЬСЯ** *сов.*—1. (*свернуться в трубку*) төргәкләнү, төрелү; 2. киезләнү; *шерсть скаталась* — йон киезләнгән.

**СКАТЕРЁТКА, СКАТЁРКА** *ж. просторeч.*— кечкенә эскәтер, кечкенә ашъяулык.

**СКА'ТЕРТНИК** *м.*, **СКА'ТЕРТНИЦА** *ж. спец.*— эскәтерләр тукучы, ашъяулыклар тукучы (мастер).

**СКА'ТЕРТНЫЙ** — 1. эскәтер...-ы, ашъяулык...-ы; *скатертная бахрома* — ашъяулык чугы; 2. эскәтер(ләр) туку...-ы, ашъяулык(лар) туку...-ы; *скатертное производство* — ашъяулыклар туку производствосы.

**СКА'ТЕРТЬ** *ж.*—1. эскәтер, ашъяулык; 2. *перен. поэт.* җәймә. ◇ **Скатертью дорога** — к. дорога.

**СКАТИ'ТЬ** I *сов.*— төшерү, тәгәрәтеп төшерү; *скатить бочку* — мичкәне тәгәрәтеп төшерү.

**СКАТИ'ТЬ** II *сов. просторeч.*— (су) сибү, (су) йөгертү.

**СКАТИ'ТЬСЯ** I *сов.*— тәгәрәү, тәгәрәп төшү, шуып төшү.

**СКАТИ'ТЬСЯ** II *сов. просторeч.*— к. окатиться.

**СКА'ТКА** I *ж.*—1. *только ед.* к. скатать 1, 2, 3; 2. *воен.* скатка (төрелгән шинель).

**СКА'ТКА** II *ж.*— к. скатить I.

**СКАТНО'Й, СКА'ТНЫЙ** I *спец.*— эре түгәрәк һәм тигез (энҗе бөртеге турында).

**СКА'ТНЫЙ** II *спец.*— скат...-ы; тугым бөгү...-ы; *скатный стан* — тугым бөгү станы.

**СКА'ТЫВАТЬ** I *несов.*— к. скатать.

**СКА'ТЫВАТЬ** II *несов.*— к. скатить I.

**СКА'ТЫВАТЬСЯ** I *несов.*—1. к. скататься; 2. *страд.* түгәрәкләп төрелү; әвәләп ясалу; 3. *страд.* басылу (киез итек турында).

**СКА'ТЫВАТЬСЯ** II *несов.*—1. к. скатиться I; 2. *страд.* төшерелү, тәгәрәтеп төшерелү.

**СКА'ТЫШ** *м. разг.*— әвәләп ясалган шарчык (төер).

**СКАТЬ** *несов. обл.*—1. ишү, кату; *скать верёвку* — бау ишү; 2. җәю; *ски тесто скалкой* — камырны уклау белән җәй; 3. *спец.* үреп ясау (филигран әйберләр турында).

**СКА'УТ** *м.*— скаут, бой-скаут.

**СКАФА'НДР** *м.*— скафандр (1. водолазлар киеме; 2. стратонавтлар киеме).

**СКАЧА'ТЬ** *сов. спец.*— суыртып алып бетерү, суыртып чыгару.

**СКА'ЧИВАТЬ** I *несов. просторeч.*— к. скатить II.

**СКА'ЧИВАТЬ** II *несов. спец.*— к. скачать.

**СКА'ЧИВАТЬСЯ** I *несов. просторeч.*— 1. к. скатиться II; 2. *страд.* (су) сибелү, (су) йөгертелү.

**СКА'ЧИВАТЬСЯ** II *несов. страд. спец.*— суыртып чыгарылу, суыртып алып бетерелү.

**СКА'ЧКА** *ж.*—1. к. скакать 1, 2; 2. *преимущ. мн.* ат(лар) чабышы, бәйге.

**СКАЧКООБРА'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книжн.*— сикерешлелек, сикерешле булу.

**СКАЧКООБРА'ЗНЫЙ** *книжн.*— сикерешле.

**СКАЧО'К** *м.*—1. сикерү; 2. *перен.* сикереш; 3. *обл.* чикерткә (гомумән сикерүче бөҗәк).

**СКА'ШИВАТЬ** I *несов.*—1. чабу, чабып

алу; 2. *перен.* кыру, кырып бетерү, һәлак итү, һәлак итеп бетерү.

**СКА'ШИВАТЬ** II *несов.*—кыегайту, кыйшайту, чалышайту.

**СКА'ШИВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — 1. чабылу, чабып алыну; 2. *перен.* кырылу, һәлак ителү, кырып бетерелү, һәлак итеп бетерелү.

**СКА'ШИВАТЬСЯ** II *несов.* — 1. *разг.* к. скоситься; 2. *страд.* кыегайтылу, кыйшайтылу, чалышайтылу.

**СКА'ЩИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. скостить.

**СКА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — төшерелү; киметелү, чигерелү.

**СКВА'ЖИНА** *ж.* — 1. *(отверстие, щель)* тишек, ярык; 2. *тех.* скважина.

**СКВА'ЖИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет. *физ. геол.* — к. скважность.

**СКВА'ЖИСТЫЙ** *физ. геол.* — тишеклетишек-тишек.

**СКВА'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет. *физ. геол.*—тишек-тишек булу, тишекле булу.

**СКВА'ЖНЫЙ** *физ. геол.* — к. скважистый.

**СКВА'ЙР** *м.* — сквайр (1. Англиядә алпавыт исеменә кушып әйтелә торган сүз; 2. Англиядә — дворяннарның почётлы титулы; АКШ та — хезмәттәге кешенең почётлы титулы).

**СКВАЛЫ'ГА** *м.* и *ж. простореч. презрит.* — к. скаред.

**СКВАЛЫ'ЖИТЬ** *несов. простореч. презрит.* — к. скредничать.

**СКВАЛЫ'ЖНИК** *м.*, **СКВАЛЫ'ЖНИЦА** *ж. простореч. презрит.* — к. скаред.

**СКВАЛЫ'ЖНИЧАТЬ** *несов. простореч. презрит.* — к. скредничать.

**СКВАЛЫ'ЖНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет. *простореч. презрит.* — к. скаредность.

**СКВАЛЫ'ЖНЫЙ** *простореч. презрит.*— 1. к. скаредный; 2. к. сквалыжнический.

**СКВА'СИТЬ** *сов. спец.* — 1. әчетү; 2. *(о молоке)* оету.

**СКВА'СИТЬСЯ** *сов. спец.* — 1. әчү; 2. *(о молоке)* оюю.

**СКВА'ШИВАТЬ** *несов. спец.* — к. сквасить.

**СКВА'ШИВАТЬСЯ** *несов. спец.* — 1. к. скваситься; 2. *страд.* әчетелү (мәсәлән, кәбестә турында); оетылу (сөт турында).

**СКВЕР** *м.* — сквер (шәһәрләрдә кечкенә бакча).

**СКВЕ'РНА** *ж. мн.* нет, *собир. церк.-книж., теперь ритор. презрит.* — кабахәтлекләр, әшәкелекләр; нәҗеслек.

**СКВЕРНА'ВЕЦ** *м.*, **СКВЕРНА'ВКА** *ж. простореч. бран.* — кабахәт кеше, әшәке (пычрак) кеше.

**СКВЕРНЕ'ТЬ** *несов. простореч. фам.* — начарлана бару, кабахәтләнә бару, шакшылана бару, нәҗесләнә бару.

**СКВЕРНИ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — пычрату, әшәкеләндерү, шакшыландыру, нәҗесләндерү.

**СКВЕ'РНО** — начар. ◇ **Мне скверно** — минем хәлем начар.

**СКВЕРНОСЛО'В** *м.*, **СКВЕРНОСЛО'ВЕЦ** *м. неодобр.* — начар сүзле кеше, әшәке сүзле кеше, пычрак сүзле кеше, оятсыз сүзләр әйтеп сүгенүче.

**СКВЕРНОСЛО'ВИЕ** *ср. мн.* нет — әшәке сүзләр, әдәпсез сүзләр, сүгенү сүзләре.

**СКВЕРНОСЛО'ВИТЬ** *несов.* — сүгенү, әдәпсез сүзләр (сүгенү сүзләре) кушып сөйләү, пычрак сүзләр әйтү.

**СКВЕРНОСЛО'ВКА** *ж. неодобр.* — к. сквернослов.

**СКВЕ'РНОСТЬ** *ж. разг.* — 1. начарлык; 2. түбәнлек, әшәкелек, кабахәтлек.

**СКВЕ'РНЫЙ** — 1. начар, түбән, әшәке, кабахәт, әдәпсез; *скверный человек* — түбән кеше; 2. *разг.* начар; *скверная работа* — начар эш.

**СКВИТА'ТЬ** *сов. разг.* — кайтару, кайтарып бирү.

**СКВИТА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — өзешү (мәсәлән, исәп-хисапны); исәп-хисапны өзү, кайтару, кайтарып бирү.

**СКВИ'ТЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. сквитать.

**СКВИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. сквитаться; 2. *страд.* кайтарылу, кайтарып бирелү.

**СКВОЗИ'СТЫЙ** *обл.* — к. скважистый.

**СКВОЗИ'ТЬ** *несов.* — 1. үтәли җил исү, үтәли җил йөрү (җил турында), җил уйнау; *закройте дверь, сквозит* — ишекне ябыгыз, үтәли җил йөри; 2. *разг.* сирәк булу, үтә күренү; *материя сквозит* — сирәк тукыма; 3. *(виднеться сквозь что-н.)* күренү, күренеп тору; 4. *перен.* сизелү, сизелеп тору, беленү, беленеп тору; *в её словах сквозило неудовольствие* — аның сүзләреннән канәгатьсезлеге сизелеп тора иде.

**СКВОЗНО'Й** — 1. үтәли чыккан, үтәли; *сквозная дыра* — үтәли чыккан тишек; 2. *разг.* турыдан-туры бара торган; *сквозной поезд* — турыдан-туры бара торган поезд; 3. *перен.* тоташ, өзлексез; *сквозной контроль* — өзлексез контроль; 4. сирәк, үтәли күренә торган.

**СКВОЗНЯ'К** *м.* — үтәли җил, аркылы йөри торган җил.

**СКВОЗЬ** I *предлог с вин. п.* — аша, аркылы, үтәли.

**СКВОЗЬ** II *нареч. простореч.* — к. насквозь.

**СКВОРЕ'Ц** *м.* — сыерчык.

**СКВОРЕ'ЧНИК** *м.* — 1. сыерчык оясы; 2. *разг.* *(любитель скворцов)* сыерчык сөюче (яратучы).

**СКВОРЕ'ЧНИЦА** *ж.* — к. скворечник 1.

**СКВОРЕ'ЧНЫЙ** *разг.* — 1. сыерчык оясы...-ы; *скворечный шест* — сыерчык оясының колгасы; 2. сыерчыклар тоту...-ы; *скворечный промысел* — сыерчыклар тоту кәсебе.

**СКВОРЕ'ШНЯ** *ж. обл.* — к. скворечник 1.

**СКВО'РКА** *ж.* — 1. *(самка скворца)* ана сыерчык; 2. сыерчыккай.

**СКЕЛЕ'Т** *м.* — 1. скелет; *скелет человека* — кеше скелеты; 2. нигез, каркас; *железобетонный скелет здания* — бинаның тимербетон каркасы; 3. *перен. книж.* ни-

гез, схема; *скелет романа* — романның схемасы.

**СКЕ'ПСИС** *м. мн.* нет, *книж. филос.* — к. скептицизм 2.

**СКЕ'ПТИК** *м.* — 1. *филос.* скептик, скептицизм тарафдары; 2. скептик, бернәрсәгә дә ышанмаучы кеше, шикләнүче кеше.

**СКЕПТИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — 1. *филос.* скептицизм (идеалистик философиядә объектив чынбарлыкны танып белү мөмкинлеген инкарь итә торган юнәлеш); 2. скептицизм, шикләнүчәнлек, ышанмаучанлык.

**СКЕПТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *филос.* скептицизм...-ы; *скептическая философия* — скептицизм философиясе; 2. скептик, ышанмаучан, шикләнүчән; *скептический взгляд* — скептик караш.

**СКЕПТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — скептиклык, ышанмаучанлык, шикләнүчәнлек.

**СКЕПТИ'ЧНЫЙ** — к. скептический 2.

**СКЕ'РЦО** *ср. нескл. муз.* — скерцо (кечкенә музыкаль әсәр).

**СКЕ'ТИНГ-РИ'НГ** *м. спорт.* — скетингринг (роликлы тимераякта шуу өчен ясалган махсус мәйданчык).

**СКЕ'ТЧ** *м.* — скетч (1. *театр.* гадәттә ачык сәхнәләрдә, циркларда, мюзик-холларда куела торган шаян эчтәлекле кыска спектакль; 2. *лит. живоп.* к. набросок).

**СКИДАВА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. скидать 1, скинуть.

**СКИДА'ЛЬЩИК** *м. с.-х.* — ташлап торучы (мәсәлән, урылган игенне).

**СКИДА'ТЬ** I *сов. простореч.* — 1. (бер урынга) ыргытып өю, ыргытып өеп кую; *скидать камни в кучу* — ташларны бер урынга ыргытып өеп кую; 2. ташлау, ыргыту, ташлап бетерү, ыргытып бетерү; ...-ып төшерү; *скидать снег с крыши* — карны түбәдән ташлау.

**СКИДА'ТЬ** II *несов. простореч.* — к. скидывать.

**СКИДА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — өеп куелу, ыргытылу, ташлану.

**СКИ'ДКА** *ж.* — 1. *простореч.* к. скинуть; 2. скидка, ташлама; 3. *охот.* (качып чабып барганда) читкә сикерү (хайваннар турында).

**СКИДНО'Й** *спец.* — алынмалы; *скидная крышка* — алынмалы капкач.

**СКИ'ДЫВАТЬ** *несов.* — к. скинуть, скидать I.

**СКИ'ДЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — 1. (бер урынга) өеп куелу, ыргытылу; ташлану, ташлап бетерелү, ыргытып бетерелү; 2. төшерелү; 3. салыну, салып ташлану (кием турында).

**СКИ'НУТЬ** *сов.* — 1. ташлау, төшерү; *скинуть мешок со спины* — капчыкны җилкәдән төшерү; 2. *разг.* салу, салып ташлау; салдыру; салдырып алу; *скинуть с себя шубу* — тунны салып ташлау; *скиньте с меня шубу* — тунымны салдырып алыгыз; 3. *разг.* киметү, киметә төшү, чигерү; *скинь два рубля* — ике сумга кимет; 4. *обл.* салу; *кобылица скинула жеребёнка* — бия колынын салган; 5. *простореч. (срыгнуть)* кире чыгару (ашаганны). ◇ **Скинуть со счетов** — к. счёт.

**СКИ'ПАТЬСЯ** *несов. спец.* — к. скипеться.

**СКУ'ШАТЬ** *сов.* — ашау, ашап бетерү.

**СЛА'БЕНЬКИЙ** *разг.* — хәлсез, көчсез, зәгыйфь.

**СЛАБЕ'ТЬ** *несов.* — 1. көчсезләнү, зәгыйфьләнү, хәлсезләнү; *память моя начала слабеть* — хәтерем зәгыйфьләнә башлады; 2. йомшау (эч); 3. какшау (сәламәтлек); 4. йомшару, басылу, басыла төшү, киму; *ветер слабеет* — җил басыла.

**СЛАБИНА'** *ж. мн.* нет — 1. салпырайган урын, бушайган урын (мәсәлән, тарттырып куйган бауда); 2. ныклы булмаган урын, ныгып җитмәгән урын (мәсәлән, бозда).

**СЛАБИ'ТЕЛЬНОЕ** *ср. в знач. сущ.* — эч йомшарткыч.

**СЛАБИ'ТЕЛЬНЫЙ** — эч йомшарта торган, эч китәрә торган, эч йомшарткыч.

**СЛА'БИТЬ** *несов.* — 1. *безл.* эч(ен) җибәрү, эч(ен) китәрү, эч китү; *его слабит* — аның эче китә; 2. эчне йомшарту; *касторка хорошо слабит* — касторка эчне яхшы йомшарта.

**СЛА'БКИЙ** *обл.* — к. слабый.

**СЛА'БНУТЬ** *несов.*— 1. *простореч.* к. слабеть; 2. (*делаться слабым*) бушаю (мәсәлән, тарттырып бәйләнгән бау).

**СЛАБОВО'ЛИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— ихтыяр йомшаклыгы, бирешүчәнлек, үзен-үзе тота алмау, ихтыярсызлык.

**СЛАБОВО'ЛЬНЫЙ** *книж.*— бирешүчән, үзен-үзе тота алмый торган, ихтыярсыз.

**СЛАБОГРУ'ДОСТЬ** *ж. мн.* нет — үпкәләре авыру булу.

**СЛАБОГРУ'ДЫЙ** — авыру үпкәле.

**СЛАБОДУ'ШИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— рухи зәгыйфьлек, аумакайлык, фикерендә нык тора алмау, рухи интереслары булмау.

**СЛАБОДУ'ШНЫЙ** *книж.*—рухи зәгыйфь, аумакай, үз фикерендә тора алмый торган, рухи интереслары булмаган.

**СЛАБОНЕ'РВНЫЙ** *книж.*— йомшак нервлы, нервлары какшаган.

**СЛАБОСИ'ЛИЕ** *ср. мн.* нет — көчсезлек, хәлсезлек, бетерешкәнлек.

**СЛАБОСИ'ЛЬНЫЙ** —1. көчсез, хәлсез, бетерешкән; 2. *спец.* аз җегәрле, аз көчле; *слабосильный мотор* — аз җегәрле мотор.

**СЛА'БОСТЬ** *ж.*— 1. *только ед.* зәгыйфьлек, хәлсезлек, көчсезлек; *чувство слабости* — хәлсезлек тойгысы; *общая слабость организма* — организмның гомуми хәлсезлеге; 2. йомшаклык, әкренлек, көчсезлек; *слабость ветра* — җилнең йомшаклыгы (әкренлеге); *проявить слабость в осуществлении решений* — карарларны тормышка ашыруда йомшаклык күрсәтү; 3. *перен.* житешсезлек, йомшаклык, йомшак як; *знали они за собой эту слабость* (Чехов) — алар үзләренең бу житешсезлекләрен (йомшаклыкларын) беләләр иде.

**СЛАБОТО'ЧНЫЙ** *тех.*— аз токлы, аз ток таләп итә торган, аз ток белән эшли торган; *слаботочная промышленность* — аз ток таләп итә торган промышленность.

**СЛАБОУ'ЗДЫЙ** *спец.*— йөгән тыңлаучан (ат).

**СЛАБОУ'МИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— акылга зәгыйфьлек, акыл зәгыйфьлеге, ахмаклык, аңгыралык.

**СЛАБОУ'МНЫЙ** *книж.*— акылга зәгыйфь, ахмак, ангыра.

**СЛАБОХАРА'КТЕРНОСТЬ** *ж. мн.* нет — йомшак характерлылык.

**СЛАБОХАРА'КТЕРНЫЙ** *книж.*—йомшак характерлы.

**СЛА'БЫЙ** —1. йомшак, зәгыйфь, көчсез; *слабый голос* — зәгыйфь тавыш; *слабая память* — зәгыйфь хәтер; *слабые мышцы* — көчсез мускуллар; 2. чирләшкә, авыру; *слабый ребёнок* — чирләшкә бала; 3. аз гына, кечкенә генә; *слабые надежды* — аз гына (кечкенә генә) өмет; *слабая улыбка* — аз гына елмаю, көлемсерәү; 4. *перен.* йомшак, тотрыксыз; *слабый характер* — йомшак характер; 5. аз җегәрле, аз көчле; *слабый мотор* — аз җегәрле мотор; 6. әкрен, салмак; *слабое течение* — әкрен агым; 7. җиңелчә; *слабый вздох* — җиңелчә көрсенү; 8 (*не тугой*) буш, салпы. ◇ **Слабая струна (струнка), слабая сторона** или **слабое место** — кимчелек, йомшак як, житешсезлек. **У него слабый желудок** — аның эче китә, аның эче йомшак.

**СЛА'ВА** *ж. мн.* нет —1. дан, шөһрәт; 2. *разг.* (*слухи, молва*) юк-бар сүзләр, имеш-мимешләр; 3. гомум фикер, сүз; *о ней идёт хорошая слава* — аның турында яхшы сүз йөри; *о нём идёт дурная слава* — аның турында начар сүз йөри; 4. мактау җыры, мәдхия. ◇ **На славу** *разг.*— бик шәп, бик яхшы; *спектакль вышел на славу* (Чехов) — спектакль бик яхшы килеп чыкты. **Одна слава, что он талантлив, а работы никакой** — аны талантлы дип йөргән булалар (атыйлар) гына, ә бернинди эше юк.

**СЛАВИ'РОВАТЬ** *сов.*— к. лавировать 2.

**СЛАВИ'СТ** *м.*— славист (славян филологиясе белгече).

**СЛАВИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *филол.*— славистика, славяноведение.

**СЛАВИСТИ'ЧЕСКИЙ** *филол.*— славистика ...-ы; *славистическое отделение* — славистика бүлеге.

**СЛА'ВИТЬ** *несов.*—1. мактау, данлыклау, мәдхия уку; *народ славит передовиков производства* — халык производство алдынгыларын мактый (данлыклый); 2. яман атын сату, гайбәтен сату; *славить кого-н. по всему городу* — бөтен шәһәрдә берәр кешенең гайбәтен сату. ◇ **Славить гостя** — кунакны мактап җырлау.

**СЛА'ВИТЬСЯ** *несов.*—1. шөһрәт казану, дан казану; *славиться своим голосом* — тавышың белән дан казану; 2. *страд.* макталу, даны таратылу; 3. яман аты сатылу, гайбәте сатылу.

**СЛА'ВИЦА** *ж. устар. обл.*— мактау җыры.

**СЛА'ВКА** *ж. зоол.*— чебенче (кош).

**СЛА'ВНЕНЬКИЙ** *разг. фам.*— яхшы гына, әйбәт кенә, чибәр генә.

**СЛА'ВНЫЙ** —1. (*пользующийся славой*) данлыклы, данлы, атаклы; 2. *разг.* бик яхшы, чибәр, бик әйбәт, сөйкемле; *славный ребёнок* — бик сөйкемле бала.

**СЛАВОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж. устар.*— дан сөюче, данлыклы булырга тырышучы.

**СЛАВОЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— данлыклы булырга тырышу, дан сөю.

**СЛАВОСЛО'ВИЕ** *ср. книж.*— артык мактау, артык күтәрү, күкләргә күтәрү, мәдхияләр уку.

**СЛАВОСЛО'ВИТЬ** *несов. неодобр.*— артык мактау, күкләргә күтәрү.

**СЛА'ВУШКА** *ж. простореч. ирон.*— к. слава 2, 3.

**СЛАВЯ'НЕ** *мн.*— славяннар, славян халкы (Европада тел һәм культура ягыннан тугандаш булган халыкларның иң зур группасы).

**СЛАВЯНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— славяннаштыру, славян гадәтләрен кертү.

**СЛАВЯНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— славяннаштыру, славян гадәтләрен кертү.

**СЛАВЯНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.*—1. славяннашу, славянга әйләнү,

славян гореф-гадәтләрен алу; 2. *страд.* славянлаштырылу, славянга әйләндерелү.

**СЛАВЯНИ'ЗМ** *м.*— славянизм, славянчылык (1. теге яки бу телдә славян телләреннең берсеннән кергән сүзләр, тәгъбирләр; 2. *лингв. лит.* славяннарның чиркәү (дини) теленнән рус теленә кергән сүз яки тәгъбир).

**СЛАВЯНОВЕ'Д** *м.*— к. славист.

**СЛАВЯНОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — славяннар турындагы фән(нәр), славяноведение (славян телләрен, әдәбиятын, культурасын, тарихын һәм славяннар тормышын өйрәнә торган фәннәр).

**СЛАВЯНОФИ'Л** *м. книж. истор.*— славянофил (славяннарның телен, гореф-гадәтләрен һ. б. яратучы).

**СЛАВЯНОФИ'ЛЬСКИЙ** — славянофил ...-ы; славянофиллар ...-ы; ***славянофильское учение*** — славянофиллар өйрәтүе.

**СЛАВЯНОФИ'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. истор.*— славянофиллык (19 йөз урталарында рус либераль алпавытларының интересларын яклаган консерватив агым. Бу агымның вәкилләре, Россия үзенең тарихи үсешендә үз юлы белән генә барырга тиеш, Көнбатыш Европа культурасыннан һәм сыйныфлар көрәшеннән сакланып калырга тиеш, дип санаганнар).

**СЛАВЯНОФИ'ЛЬСТВОВАТЬ** *несов. книж. ирон.*— славянофил булу, славянофиллык карашларын яклау.

**СЛАВЯНОФО'Б** *м. книж. истор.*— славянофоб (славяннар теленә, гореф-гадәтләренә һ. б. нәфрәт белән караучы).

**СЛАВЯНОФО'БСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. истор.*— славянофоблык, славяннарга дошманлык.

**СЛАВЯ'НСКИЙ** — славян ...-ы; ***славянские языки*** — славян телләре.

**СЛАВЯ'НСТВО** *ср. мн.* нет — 1. славян халыклары; 2. славянлык.

**СЛАГА'ЕМОЕ** *ср.*— 1. *мат.* кушылучы, кушыла торган сан; 2. кушылма.

**СЛАГА'ТЬ** *несов.*— 1. язу, (уйлап) чыгару, төзү; ***слагать песню*** — җыр язу (чыгару); 2. бушату; ***слагать груз*** — йөкне бушату; 3. *перен.* өстеннән төшерү (җаваплылыкны).

**СЛАГА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. сложиться 3, 4; 2. төзелү; 3. *страд.* язылу, уйлап чыгарылу, төзелү; 4. *страд.* бушатылу, өстеннән төшерелү (җаваплылык).

**СЛАД** *м.*: **сладу нет** *разг.*— тезгенләп булмый, авызлыклап булмый, буйсындырып булмый, игә китереп булмый.

**СЛА'ДЕНЬКИЙ** *разг.*— шикәрле, татлы, баллы.

**СЛА'ДИТЬ** *сов. разг.*—1. ипләү, көйләү, җайлау, җайга салу; 2. җиңү, буйсындыру, авызлыклау, игә китерү; ***с нервами сладить трудно*** — нервларны игә китерү кыен.

**СЛА'ДИТЬСЯ** *сов. разг.*— 1. ипләнү, көйләнү, җайга салыну; 2. *простореч.* (*прийти к соглашению*) килешү.

**СЛА'ДКИЙ** —1. татлы; шикәрле, баллы; ***сладкий мёд*** — татлы бал; 2. *обл.* тозланмаган; яңа сауган; ***сладкое молоко*** — яңа сауган сөт; ***сладкие огурцы*** — тозланмаган кыяр; 3. *перен.* татлы, тәмле, рәхәт; ***сладкий сон*** — тәмле йокы; ***сладкие мечты*** — татлы хыяллар; 4. *поэт.* назлы, ягымлы; ***сладкие звуки арфы*** — арфаның ягымлы тавышлары; 5. *перен. неодобр.*— төче; ***сладкая улыбка*** — төче елмаю; ***сладкие фразы*** — төче фразалар.

**СЛА'ДКО** *нареч.*— татлы итеп, шикәрлебаллы итеп.

**СЛАДКОВА'ТЫЙ** — төчкелтем, беркадәр татлы.

**СЛАДКОГЛА'СИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— тавыш ягымлылыгы, тавыш нәфислеге.

**СЛАДКОГЛА'СНЫЙ** *книж. устар.*— ягымлы тавышлы, нәфис тавышлы.

**СЛА'ДКОЕ** *ср. в знач. сущ.*— татлы ашамлык.

**СЛАДКОЕ'ЖКА** *м.* и *ж. разг.*— татлы аш сөюче, тәмле тамак.

**СЛАДКОЗВУ'ЧИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— аһәңлелек, ягымлы тавышлылык.

**СЛАДКОЗВУ'ЧНЫЙ** *книж. устар.*— аһәңле, ягымлы тавышлы.

**СЛАДКОРЕЧИ'ВЫЙ** *книж. устар.*— татлы телле, төче телле.

**СЛА'ДОСТНЫЙ** *книж. поэт.*— татлы; ***сладостные мечты*** — татлы хыяллар.

**СЛАДОСТРА'СТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— (җенси) дәрт, шәһвәт.

**СЛАДОСТРА'СТНИК** *м.*, **СЛАДОСТРА'СТНИЦА** *ж. книж. неодобр. устар.*— шәһвәтле кеше, җенси дәрткә артык бирелүчән кеше.

**СЛАДОСТРА'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— шәһвәтлелек, (җенси) дәртлелек.

**СЛАДОСТРА'СТНЫЙ** *книж.*— шәһвәтле, (җенси) дәртле.

**СЛА'ДОСТЬ** *ж.*—1. татлылык, татлы тәм; 2. рәхәтлек; 3. ягымлылык; 4. назлылык; 5. *только мн.* татлы ашамлыклар; ***восточные сладости*** — көнчыгыш халыкларының татлы ашамлыклары.

**СЛА'ЖЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— иплелек, җайга салынганлык.

**СЛА'ЖЕННЫЙ** *разг.*—ипле, җайга салынган; ***слаженная работа*** — җайга салынган эш.

**СЛА'ЖИВАТЬ** *несов разг.*— ипләү, җайга салу.

**СЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— ипләнү, җайга салыну.

**СЛА'ЗАТЬ** *сов. разг.*— к. слазить I.

**СЛА'ЗИТЬ** I *сов. разг.*— 1. төшеп менү; ***слазить в погреб за молоком*** — базга сөт алырга төшеп менү; 2. менеп төшү; ***слазить на чердак*** — чарлакка менеп төшү.

**СЛА'ЗИТЬ** II *несов. обл.*— к. слезать.

**СЛА'ЛОМ** *м. спорт.*— слалом (чаңгы ярышының бер төре — төрле кыенлыкларны җиңеп таудан чаңгы белән тиз шуып төшү ярышы).

**СЛА'ЛОМНЫЙ** — слалом...-ы; ***слаломные лыжи*** — слалом чаңгысы.

**СЛА'ЛОМЩИК** *м. спорт.*—слаломчы (слалом ярышында катнашучы чаңгычы).

**СЛА'МЫВАТЬ** *несов.*— к. сломить.

**СЛА'МЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. сломиться; 2. *страд.* сындырылу.

**СЛА'НЕЦ** *м. геол.*— сланец (катлау-катлау тау токымы).

**СЛАНЦЕВА'ТОСТЬ** *ж. мн. нет, геол.*— (тау токымнарының) катлаулану үзенчәлеге.

**СЛА'НЦЕВЫЙ** — 1. *геол.* катлаулы, катламлы; *сланцевые породы* — катламлы тау токымнары; 2. сланец...-ы; *сланцевая промышленность* — сланец промышленносте.

**СЛАНЬ** *ж. обл.*— түшәү, түшәүлек.

**СЛАСТЁНА** *м.* и *ж. разг. фам.*— тәмле тамак.

**СЛАСТИ'ТЬ** *несов.*—шикәрле итү, ширбәтләү, татлы итү, баллау, татлыландыру.

**СЛАСТИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — шикәрле ителү, ширбәтләнү, баллы ителү, татлыландырылу.

**СЛАСТОЛЮ'БЕЦ** *м. книж. устар.*— шәһвәтле кеше, җенси ләрткә артык бирелүчән кеше.

**СЛАСТОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж. устар.*— шәһвәтле, (җенси) дәртле.

**СЛАСТОЛЮ'БИЕ** *ср. мн. нет, книж. устар.*— шәһвәт, (җенси) дәрт.

**СЛАСТЬ** *ж.*— 1. *только мн.* татлы ашамлыклар; *купить детям сластей*—балаларга татлы ашамлыклар сатып алу; 2. *только ед. разг.* баллылык, татлылык; *сласти мало в этих пряниках* — бу прянikларның татлылыгы бик аз; 3. *только ед. перен. простореч.* рәхәт, рәхәтлек. ◇ **В сласть** — к. всласть.

**СЛАТЬ** *несов.*— җибәрү; *слать письма*— хатлар җибәрү.

**СЛА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. күрсәтеп китү, таяну (икенче берәүгә яки аның язганына); 2. *страд.* җибәрелү (хат һ. б.).

**СЛАЩА'ВО** *нареч.*— төче; *слащаво улыбнуться* — төче елмаю.

**СЛАЩА'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. артык баллы булу, бик шикәрле булу, артык татлы (ширбәтле) булу; 2. *перен. неодобр.* үтә назлылык, төчелек (кыланышта, сүздә).

**СЛАЩА'ВЫЙ** *разг.*— 1. артык баллы, бик шикәрле, ширбәтле, артык татлы; 2. *перен. неодобр.* үтә назлы, төче; *слащавая улыбка* — төче елмаю.

**СЛА'ЩЕ** — татлырак, баллырак. ◇ **Хрен редьки не слаще** — керән тормадан татлы булмас.

**СЛАЩЁННЫЙ** *разг.*— татлылатылган, татлы ителгән, татлыландырылган, ширбәтләндер(ел)гән.

**СЛЕ'ВА** *нареч.*— сулда, сул якта; сулдан, сул яктан.

**СЛЕГА'** *ж. спец.*— колга, шикмә (өй түбәсендә бәпкәгә аркылы салына торган агач).

**СЛЕГКА'** *нареч.*— 1. җиңелчә генә; аз гына, бераз; *губы слегка дрожали* — иреннәре аз гына калтырый иде; 2. (*мимоходом*) өстән-өстән генә,читләтеп кенә, сүз җаенда гына, сүз уңаенда гына.

**СЛЕД** I *м.*— 1. эз; *след от саней* — чана эзе; 2. *перен.* билге, эз; *следы преступления* — җинаять эзләре; 3. *разг.* аяк табаны ◇ **Не остыл ещё след** — эзе югалмаган әле. **Исчез без следа** — эзсез югалды, эзе дә калмады. **Во след** — эзеннән. **Замести след** — эзен югалту. **По свежим следам** — эзне югалтмыйча бару. **След простыл** — эзе дә юк.

**СЛЕД** II: **не след** *простореч.*— ярамый.

**СЛЕДИ'ТЬ** *несов.*— 1. күзәтү, күзәтеп тору, карау, карап тору; *он с интересом следил, как поднимался аэростат* — ул аэростатның күтәрелгәнен кызыксынып карап торды; *следить за детьми* — балаларны күзәтеп тору (күзәтү); 2. *перен.* (берәр нәрсәнең барышы, үсеше белән) кызыксыну, күзәтә бару; *следить за успехами науки* — фәннең казанышларын күзәтә бару; 3. *охот.* эзеннән барып табу, эзәрлекләү, эзләп бару, эзәрләү; *в свежую порошу хорошо зайца следить* (Даль)— яңа яуган кырпак кардагы эзләреннән барып куянны табу җиңел; 4. *разг.* пычрак эз калдыру, пычрату; *следить мокрыми сапогами на полу* — юеш итектән йөреп идәнне пычрату. ◇ **Следить за порядком** — тәртип саклау.

**СЛЕ'ДОВАНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. бару; *во время следования поезда* — поезд барганда; 2. ияру; *следование новой моде* — яңа модага ияру; 3. тикшерү, эзенә төшү; *следование запутанного дела* — буталчык эшне тикшерү.

**СЛЕ'ДОВАТЕЛЬ** *м. офиц.* — следователь, суд тикшерүчесе, тикшерүче.

**СЛЕ'ДОВАТЕЛЬНО** *книж.*— 1. *союз* шуның өчен, шуның нәтиҗәсендә, шуңа күрә; 2. димәк, шулай итеп, шулай булгач; *следовательно, я прав* — димәк, мин хаклы.

**СЛЕ'ДОВАТЕЛЬСКИЙ** *офиц.*— следователь...-ы; суд тикшерүчесенең ...-ы, тикшерүче ...-ы; *следовательские показания* — суд тикшерүчесенең күрсәтүләре.

**СЛЕ'ДОВАТЬ** *несов.*— 1. ияреп бару, артыннан бару, артыннан килү; *следуйте за мной* — минем артымнан барыгыз; 2. ияру; *следовать учению Дарвина* — Дарвин өйрәтүенә ияру; 3. *книж. устар.* күзәтеп бару; *следовать за текущей литературой* — агымдагы әдәбиятны күзәтеп бару; 4. чыгып (булып) тору, ...артыннан килү, берсе артыннан икенчесе килү; *за весной следует лето* — яз артыннан җәй килә; *одно событие следовало за другим* — вакыйгалар берсе артыннан икенчесе чыгып (булып) тора иде; 5. бару; *поезд следует до Казани* — поезд Казанга хәтле бара; 6. ...-нча бару, ...-нча эшләү, ...-на ияру; *следовать прихоти* — нәфес теләге буенча эшләү; *следовать внушению сердца* — йөрәк кушканча эшләү; *во всем следовал своему отцу* — һәр эштә ул этисе эшләгәнчә эшли иде (этисенә ияра иде); 7. *книж.* килеп чыгу; *отсюда следуют важные выводы* — моннан бик мөһим нәтиҗәләр килеп чыга; 8. *безл. книж.* кирәк, тиеш; *работу следует закончить* — эшне тәгәлләү (тәмам итү) кирәк; *сколько вам следует за работу?*— сезгә хезмәтегез өчен ничә сум (күпме) тиеш? 9. *устар. офиц.* суд тикшерүе алып бару, берәр эшне тикшерү. ◇ **Как**

**следует** *разг.*— тиешенчә, яхшылап, яхшы итеп; **сделать что-нибудь как следует** — берәр нәрсәне тиешенчә (яхшы итеп) эшләү. **Следовать правилам** — кагыйдә(ләр)гә буйсыну. **Как и следовало ожидать**—шулай көтелә иде дә, көткәнчә.

**СЛЕ'ДОМ** *нареч.*— артыннан ук, эзеннән ук, калышмыйча; *двигаться следом за обозом* —йөк артыннан ук бару.

**СЛЕДОПЫ'Т** *м.*— (җәнлек эзләре буенча баручы) аучы.

**СЛЕ'ДСТВЕННЫЙ** *офиц. право* — 1. тикшерү ...-ы, (суд) тикшерү (е)...-ы; *следственный материал* —(суд) тикшерү(е) материалы; 2. тикшерү алып бару ...-ы; тикшерү алып баручы; *следственные органы* — тикшерү алып бару органнары.

**СЛЕ'ДСТВИЕ** *ср.*— 1. нәтиҗә; *нет следствия без причины* — сәбәпсез нәтиҗә булмый; 2. *офиц. право* тикшерү, суд тикшерүе; *судебное следствие* — суд тикшерүе; *вести следствие* — суд тикшерүе алып бару; *под следствием* — суд тикшерүендә.

**СЛЕ'ДУЕМЫЙ** *канц.*— тиеш, тиеш булган; *следуемые мне деньги я доверяю получить тебе* — миңа тиеш булган акчаны алырга сиңа тапшырам; *отдать каждому следуемое* — һәркемгә тиешен бирү.

**СЛЕ'ДУЮЩИЙ** — 1. бара торган; *поезд, следующий до Москвы*—Мәскәүгә кадәр бара торган поезд; 2. тиешле, тиеш булган; *деньги следующие мне за работу* — миңа эш өчен тиеш булган акча; 3. таяна торган, таянып эш итә торган, ияр торган; *учёный следующий учению Дарвина* — Дарвин тәгълиматына таяна торган галим; 4. киләчәк, киләсе, алдагы, чираттагы, моннан соңгы, икенче; *на следующее утро выпал снег* — икенче (иртәгесе) көнне кар яуды; *следующий номер программы* — программаның алдагы номеры; 5. түбәндәге, мондый, менә шундый; *я придерживаюсь следующего взгляда* — мин түбәндәге карашта торам.

**СЛЕЖА'ТЬСЯ** *сов.*— озак ятып тыгызлану, басылып (ятып) укмашу (кату); *сено слежалось* — печән озак ятып укмашкан.

**СЛЁЖИВАТЬСЯ** *несов.*— к. слежаться.

**СЛЕ'ЖКА** *ж. мн.* нет — күзәтү, шымчылык итү, эзәрләү.

**СЛЕЗА'** *ж.*— 1. яшь, күз яше; 2. *только мн.* елау; *довести до слёз* — елауга илтеп җиткерү; 3. *перен.* тамчы; *слеза росы* — чык тамчысы. ◇ **Глотать слёзы** — к. глотать. **Крокодиловы слёзы** — к. крокодиловый. **Обливаться слезами** — к. обливаться. **Осушить слёзы** — к. осушить. **Сквозь слёзы** — яшь аралаш, яшь агызып. **Пролить или пустить слезу** *разг. шутл.*— елап җибәрү, елап алу. **Не пролить ни одной слезы** *перен.*— һичбер күңел бирмәү, бик салкын карау.

**СЛЕЗА'ТЬ** *несов.*— к. слезть.

**СЛЕЗИ'НКА** *ж.*— яшь бөртеге, яшь тамчысы.

**СЛЕЗИ'ТЬСЯ** *несов.*— яшь килү; *глаза слезятся* — күздән яшь килә.

**СЛЁЗКА** *ж.*— 1. яшь; 2. *спец.* (үтә күренмәле) бөртек (мәсәлән, боз бөртеге).

**СЛЕЗЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *пренебр.*— елак булу, елаклык.

**СЛЕЗЛИ'ВЫЙ** *пренебр.*— 1. елак, елаучан, яшь түгүчән; *слезливый ребёнок* — елаучан бала; 2. елак, аяныч; *слезливый голос* — елак тавыш, аяныч тавыш.

**СЛЕЗНИ'К** *м.*— 1. *истор.* к. слезница 1; 2. *анат.* яшь капчыгы (күз янында яшь җыела торган капчык).

**СЛЕЗНИ'ЦА** *ж.*— 1. *истор.* яшь савыты (борынгы римлыларда берәр кешене күмгәндә аның кардәшләре тарафыннан түгелгән яшьләр саклана торган савыт булган имеш); 2. *шутл. ирон. устар.* елап сорау, елый-елый үтенү, күз яше түгеп үтенү.

**СЛЁЗНЫЙ** — 1. яшь ...-ы; *слёзные железы* — яшь бизләре; 2. *перен. разг.* елап..., кызгандыргыч, җәлләткеч; *слёзная просьба* — елап сорау, елап үтенү, күз яше белән үтенү.

**СЛЕЗООТДЕЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *физиол.*— яшь агу, яшь килү.

**СЛЕЗООТДЕЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *физиол.*— яшь чыгара торган, яшь агыза торган, яшь китерә торган.

**СЛЕЗОТЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — яшь агу, яшь коелу, яшь килү, яшь түгелү.

**СЛЕЗОТОЧИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — яшь агу, яшь коелу, яшь килү.

**СЛЕЗОТОЧИ'ВЫЙ** — 1. яшь килә торган, яшь түгә торган, яшь ага торган; *слезоточивые глаза* — яшь килә торган күзләр; 2. яшь агыза торган; *слезоточивый газ* — яшь агыза торган газ.

**СЛЕЗОТОЧИ'ТЬ** *несов. книж.*— яшь агу, яшь коелу, яшь килү; *глаза слезоточат* — күзләрдән яшь ага.

**СЛЕЗТЬ** *сов.*— 1. (тотынып, тырмашып) төшү; *слезть с дерева* — агачтан (тырмашып) төшү; 2. төшү; *слезть; с лошади* — аттан(сикереп) төшү; *слезть на первой остановке* — беренче тукталышта төшү; 3. *простореч.* бушау; *пояс слез* — билбау бушаган; 4. кубу, кубып төшү; *кожа слезла* — тире купты; *краска слезла* — буяу купкан.

**СЛЕПЕ'НЬ** *м.*— бөгәлчән.

**СЛЕ'ПЕНЬКИЙ** *разг. фам.*— сукыр.

**СЛЕПЕ'Ц** *м.*— 1. сукыр кеше; 2. *перен.* алданган кеше, сукыр.

**СЛЕПИ'ТЬ** I. *несов.*— 1. сукырайту; 2. күзне чагылдыру, камаштыру; *солнце слепит глаза* — кояш күзне чагылдыра (камаштыра); 3. (күзне) томалау, каплау, ачарга бирмәү; *снег слепит глаза, глаза слепит снегом* — кар күзне ачарга бирми.

**СЛЕПИ'ТЬ** II *сов.*— әвәләп ясау; *слепить птичку из глины* — балчыктан әвәләп кош ясау.

**СЛЕПИ'ТЬ** III *сов.*— 1. сылап ябыштыру, җилемләп ябыштыру, ябыштырып кушу; *слепить два листа бумаги клеем* — ике бит кәгазьне җилемләп ябыштыру; 2. ябыштырып ясау; *слепить коробочку* — ябыштырып тартма ясау; 3. *перен. разг. фам*

этмәләү, этмәләп кую, эштер-өштер китерү (ясау, язу).

**СЛЕПИ'ТЬСЯ** I *несов.*— күз чагылу, күз камашу; *глаза слепятся ярким светом* — көчле яктылыктан күз чагыла.

**СЛЕПИ'ТЬСЯ** II *сов.*— ябышу; *листочки книги слепились*— китап битләре ябышканнар.

**СЛЕ'ПЛИВАТЬ** *несов. разг.*— к. слеплять.

**СЛЕ'ПЛИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. слепляться; 2. *страд.* ябыштырылу, ябыштырып ясалу.

**СЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. слепить III.

**СЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. слепиться II; 2. *страд.* ябыштырылу, ябыштырып ясалу.

**СЛЕ'ПНУТЬ** *несов.*— сукыраю, күзсез калу, күрми башлау.

**СЛЕ'ПО** *нареч.*— 1. сукырларча, уйламыйча; *слепо верить во что-н.*— берәр нәрсәгә сукырларча ышану; 2. *спец.* тонык; *слепо написано* — тонык язылган.

**СЛЕПО'Й** — 1. сукыр; 2. *спец.* тонык; *слепая печать* — тонык басма (тонык басылган китап һ. б.); 3. карамыйча, күрмичә; *слепая игра в шахматы* — шахматка карамыйча уйнау; *слепой метод писания на пишущей машинке* — язу машинкасында карамыйча язу; 4. *перен.* сукырларча...; *слепое подражание* — сукырларча ияру. ◇ **В слепую** — к. вслепую. **Слепая курица** *разг.* — сукыр тычкан, сукыр тавык (начар күрә торган кеше турында).

**СЛЕ'ПОК** *м.*— күчермә, басып төшерелгән рәсем, копия; *слепок с медали* — медальнең (сургучка, балавызга һ. б.) басып төшерелгән күчермәсе.

**СЛЕПОРОЖДЁННЫЙ** *книж.*— сукыр (булып) туган, тумыштан сукыр, тума сукыр.

**СЛЕПОТА'** *ж. мн.* нет — 1. сукырлык; 2. *перен. книж.* сукырлык, наданлык. ◇ **Душевная слепота** *мед.*— күргәнне аңламау (авыруы). **Куриная слепота** — тавык күзе. **Цветовая слепота** — к. дальтонизм. **Снежная слепота** — сарыбаш (үсемлек).

**СЛЕПУ'Н** *м. зоол.*— җир асты еланы; сукыр елан.

**СЛЕПЫ'Ш** *м.*— 1. *простореч. шутл.* или *бран.* сукыр кеше; 2. *зоол.* сукыр тычкан(ның бер төре).

**СЛЕСА'РИТЬ, СЛЕСА'РНИЧАТЬ** *несов. разг.* — слесарь булып эшләү, слесарьлык итү.

**СЛЕСА'РНАЯ** *в знач. сущ. ж.*— к. слесарня.

**СЛЕСА'РНЫЙ** — 1. слесарлык ...-ы; *слесарное ремесло* — слесарьлык һөнәре; 2. слесарь ...-ы; *слесарный инструмент* — слесарь кораллы.

**СЛЕСА'РНЯ** *ж. разг.*— слесарьлык мастерское.

**СЛЕ'САРСКИЙ** — слесарь(ның) ...-ы; *слесарский заработок* — слесарьның хезмәт хакы.

**СЛЕ'САРСТВО** *ср. мн.* нет, *простореч.*— слесарьлык, слесарь хезмәте.

**СЛЕ'САРША** *ж. разг.*— слесарь хатыны.

**СЛЕ'САРЬ** *м.*— слесарь.

**СЛЁТ** I *м.*— 1. очып килү, очып килеп җыелу; 2. *спец.* очып бер җиргә җыелган кошлар, кошлар төркеме; 3. слёт (берәр массовый оешма вәкилләренең съезды, җыелышы); *слёт пионеров* — пионерлар слёты.

**СЛЁТ** II *м. охот. спец.* — очып төшү, очып (китеп) бару; *охотник убил птицу на слёте* — аучы кошны очып (китеп) барганда атып үтерде.

**СЛЁТАННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *ав.* — бергә очарга өйрәнгәнлек, бергәләп очуда осталык; *звено тяжёлых бомбардировщиков показало высокую слётанность* — авыр бомбардировщиклар звеносы бергәләп очуда зур осталык күрсәтте.

**СЛЕТА'ТЬ** I *сов. разг.* — 1. очып барып кайту; *слетал на самолёте в Севастополь* — самолётта Севастопольгә очып барып кайттым; 2. *перен. фам.* бик тиз барып кайту (берәр җиргә).

**СЛЕТА'ТЬ** II *несов.* — к. слететь.

**СЛЕТА'ТЬСЯ** I *сов. ав.* — бергәләп очарга өйрәнү, бергә очу осталыгына ирешү.

**СЛЕТА'ТЬСЯ** II *несов.* — к. слететься.

**СЛЕТЕ'ТЬ** *сов.* — 1. очып төшү; *голубь слетел с крыши на землю* — күгәрчен өй түбәсеннән җиргә очып төште; 2. *разг.* төшеп китү; *шапка слетела* — бүрек төшеп китте; 3. *разг.* егылып төшү; *мальчик слетел с дерева* — малай агач башыннан егылып төште; 4. очып күтәрелеп китү; *бабочка слетела с цветка* — күбәләк чәчәктән очып күтәрелеп китте; 5. *перен. простореч. фам.* урыннан колак кагу, куылу, чыгарылу; *чиновник слетел за взяточничество* — чиновник взятка алган өчен урыныннан колак какты. ◇ **За худые дела слетит и голова** — яман эшләр өчен башсыз да калырсың.

**СЛЕТЕ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (очып килеп) җыелу; *воробьи слетелись на гумно* — ындырга чыпчыклар (очып килеп) җыелган; 2. *перен. разг. фам.* (йөгереп килеп) җыелу; *на место происшествия слетелось много народу* — вакыйгага булган урынга бик күп халык (йөгереп килеп) җыелды.

**СЛЁТОК** *м.* — 1. *охот.* (яңа гына оча башлаган) кош баласы; 2. *перен. разг. пренебр.* сәнәктән кирәк булган кеше.

**СЛЕЧЬ** *сов.* — 1. *разг.* авырып (урынга) егылу, авырып китү; 2. *обл.* сөрлегү, егылу (иген турында).

**СЛИ'ВА** *ж.* — слива, кара җимеш (агачы һәм җимеше).

**СЛИВА'ТЬ** *несов.* — к. слить.

**СЛИВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. слиться; 2. кушылып агу; 3. *страд.* түгелү, бушатылу, бушатып алыну; 4. *страд.* эретеп коелу, кушып эретелү, эретеп кушылу.

**СЛИ'ВКИ** *ед.* нет — 1. каймак, сөт өсте; 2. *перен.* иң яхшысы, (берәр әйбернең) иң яхшы өлеше.

**СЛИВКООТДЕЛИ'ТЕЛЬ** *м. спец.* — каймак аерткыч, сепаратор.

**СЛИВКООТДЕЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — каймак аерта торган; *сливкоотделительный аппарат* — каймак аерта торган аппарат (сепаратор).

**СЛИВНО'Й** *спец.* — 1. (төрле савытлардан бер савытка) бушатылган, җыеп кушылган, кушылган; *сливное молоко* — җыеп кушылган сөт; 2. пычрак су түгелә торган; *сливная яма* — пычрак су түгелә торган чокыр. ◇ **Сливной молочный пункт** — сөт тапшыру пункты, сөт җыю пункты.

**СЛИ'ВНЫЙ** *устар.* — к. сливовый.

**СЛИВНЯ'К** *м. обл.* — 1. кара җимеш агачлыгы; кара җимеш куаклыгы; 2. к. сливянка.

**СЛИ'ВОВЫЙ** — кара җимеш...-ы; *сливовое варенье* — кара җимеш вареньесы.

**СЛИ'ВОЧНИК** *м.* — каймак савыты.

**СЛИ'ВОЧНЫЙ** I — 1. каймак...-ы; *сливочный вкус* — каймак тәме; 2. каймактан хәзерләнгән; *сливочное мороженое* — каймактан хәзерләнгән мороженый; 3. атлан, ак; *сливочное масло* — атлан май, ак май.

**СЛИ'ВОЧНЫЙ** II *спец.* — түгелә торган, түгә торган..., бушатыла торган.

**СЛИВЯ'НКА** *ж.* — сливянка, слива белән тәнәтелгән аракы.

**СЛИЗА'ТЬ** *сов.* — 1. ялап алу, ялап чистарту; 2. ялап ашап бетерү (мәсәлән, мәче каймакны).

**СЛИЗЕВИ'К** *м. бот.* — ябышкак (күзәнәкләре бик күп ябышкак матдә бүлеп чыгара торган үсемлек).

**СЛИЗЕВО'Й** *спец.* — лайлалы, лайла чыгара торган.

**СЛИ'ЗЕНЬ** *м. зоол.* — лайлач әкәм-төкәм.

**СЛИЗЕТЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец. бот.* — лайла агу (кайбер агачларның һәм куакларның кәүсәләреннән).

**СЛИ'ЗИСТЫЙ** *книж.* — лайлалы; *слизистая оболочка* — лайлалы яры.

**СЛИ'ЗКИЙ** *обл.* — 1. лайлалы; *слизкая рыба* — лайлалы балык; 2. тайгак, бик шома, шуа торган.

**СЛИЗНУ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* ялап алу, ялап чистартып алу; 2. *перен. простореч. вульг.* сыптыру, чәлү, урлау.

**СЛИЗНЯ'К** *м.* — 1. *зоол.* моллюск; 2. *перен. разг. презрит.* ихтыярсыз, селәгәй, характерсыз кеше, боламык.

**СЛИ'ЗОВЫЙ** *спец.* — лайлалы; *слизовые грибы* — лайлалы гөмбә.

**СЛИ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. слизать.

**СЛИ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. ялап алыну, ялап чистартылу; 2. ялап ашап бетерелү.

**СЛИЗЬ** *ж. мн.* нет — лайла.

**СЛИМО'НИТЬ** *сов. вульг.* — к. лимонить.

**СЛИНЯ'ТЬ** *сов.* — 1. *простореч.* уңу, төсе китү; 2. *спец.* ябагасын кою, кабыгын салу; *шерсть слиняла* — йоны коелган.

**СЛИП** *м. мор.* — слип (судноларны ярга чыгару өчен корылган җайланма).

**СЛИПА'ТЬ** *несов. разг.* — томалау, каплау; *вьюга мне слипает очи* (Пушкин) — буран күзләремне томалый.

**СЛИПА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. ябышу; 2. *перен.* йомылу (йокы килүдән күз йомылу).

**СЛИПНУ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ябышу; 2. *перен.* (күзләр) йомылу.

**СЛИ'ТКОВЫЙ** *спец.* — коелма...; *слитковое золото* — коелма алтын.

**СЛИ'ТНО** *нареч.* — кушып, бергә; *пишется слитно* — кушып (бергә) язылa.

**СЛИ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тоташлык, тоташ булу; *слитность написания* — язуның тоташ булуы.

**СЛИ'ТНЫЙ** — тоташ. ◇ **Слитное предложение** *грам.* — тиңдәш кисәкле җөмлә.

**СЛИ'ТОК** *м.* — коелма, эретеп коелган металл; *слиток золота* — алтын коелмасы.

**СЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. түгү, бушату; *слить грязную воду в помойное ведро* — пычрак суны чүп чиләгенә түгү; 2. саркыту; *слить воду из творога* — эремчекнең суын саркыту; 3. бергә кушу, бергә кушып салу, җыеп кушып салу; *слить молоко от разных коров* — төрле сыерлардан савылган сөтне бергә кушу; 4. кою; *слить колокол* — чаң кою; 5. *спец.* кушып кою, бергә кушып кою; *слить олово со свинцом* — ак кургашын белән кара кургашынны бергә кушып кою; 6. *перен.* кушу; *слить несколько школ в одну* — берничә мәктәпне бергә кушу; 7. *разг.* агып китү, агып бетү, су кайту; *вода слила с затопленных лугов* — ташкын баскан болыннардан су кайткан.

**СЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. (агып) кушылу, катнашу; *две реки слились вместе* — ике елга бергә кушылган; 2. эреп бергә кушылу (мәсәлән, көмеш акчалар); 3. *перен.* берләшү, кушылу; *две школы слились в одну* — ике мәктәп бергә кушылды (яки берләште); 4. кушылып яңгырау (төрле тавыш).

**СЛИЧА'ТЬ** *несов.* — сличить.

**СЛИЧА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — чагыштырылу (мәсәлән, күчермә белән төп нөсхә).

**СЛИЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — чагыштырып бару...-ы; чагыштыру...-ы; *сличительная ведомость* — чагыштырып бару ведомосте.

**СЛИЧИ'ТЬ** *сов.* — чагыштырып карау, чагыштыру.

**СЛИ'ШКОМ** *нареч.* — бик, артык, чиктән тыш, кирәгеннән артык, чамасыз, ифрат, артык дәрәҗәдә; *слишком дорого* — чиктән тыш кыйммәт; *видно, она не слишком заботлива* — күрәсең, ул бик кайгыр(т)учан түгел.

**СЛИЯ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книжс.* — 1. кушу, кушылу; берегү; 2. (бергә) кушылган урын; *у слияния двух рек* — ике елга бергә кушылган урында

**СЛОБОДА'** *ж.* — 1. *истор.* зур авыл, слобода (Россиядә крепостное право яшәгән вакытта крепостной булмаган халык торган авыл); 2. (гомумән) зур авыл; 3. бистә (шәһәр янындагы посёлок).

**СЛОБО'ДКА** *ж.* — к. слобода.

**СЛОБО'ДСКИЙ, СЛОБОДСКО'Й** — зур

авыл...-ы, слобода...-ы; бистә...-ы; *слободское население* — бистә халкы.

**СЛОБОДЧА'НИН** *м.*, **СЛОБОДЧА'НКА** *ж. обл.* — к. слобожанин, слобожанка.

**СЛОБОЖА'НИН** *м.*, **СЛОБОЖА'НКА** *ж. обл.* — бистәдә торучы, бистәдә яшәүче, бистә кешесе.

**СЛОВА'КИ** *мн.* — словаклар, словак халкы (Словакиянең төп халкы, Чехословакия республикасы составына керә).

**СЛОВА'РИК** *м. разг.* — кечкенә сүзлек, кесә сүзлеге.

**СЛОВА'РНИК** *м. спец. разг.* — сүзлекче, сүзлек төзүче, сүзлекләр редакторы, лексикограф.

**СЛОВА'РНЫЙ** — **1.** сүзлек ...-ы; *словарный состав русского языка* — рус теленең сүзлек составы; **2.** сүзлекләр ...-ы; *словарное издательство* — сүзлекләр нәшрияты.

**СЛОВА'РЬ** *м.* — **1.** сүзлек; *русско-татарский словарь* — русча-татарча сүзлек; *толковый словарь* — аңлатмалы сүзлек; **2.** сүз байлыгы, (теге яки бу телнең яки язучының) сүзлек составы.

**СЛОВА'ЦКИЙ** — словак...-ы; *словацкий язык* — словак теле.

**СЛОВА'ЧКА** *ж.* — словак хатын-кызы.

**СЛОВЕ'НКА** *ж.* — словен хатын-кызы.

**СЛОВЕ'НСКИЙ** — словен...-ы; *словенский язык* — словен теле.

**СЛОВЕ'НЦЫ**, **СЛОВЕ'НЫ** *мн.* — словеннар, словен халкы (Югославия составына керә торган Словениянең төп халкы).

**СЛОВЕ'СНИК** *м.*, **СЛОВЕ'СНИЦА** *ж.* — **1.** телче, әдәбиятчы; **2.** тел-әдәбият белгече, тел-әдәбият укытучысы; **3.** телче-әдәбиятчы студент.

**СЛОВЕ'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** сүз иҗаты, әдәбият; *теория словесности* — әдәбият теориясе; **2.** *устар.* филология фәннәре (тел белеме, стилистика, әдәбият белеме һ. б.); *заниматься словесностью* — филология фәннәрен өйрәнү; **3.** *разг. шутл. пренебр.* сүз боткасы; *это только одна словесность* — бу тик сүз боткасы гына; **4.** *дореvол.* хәрби уставны өйрәнү дәресләре (армиядә).

**СЛОВЕ'СНЫЙ** — **1.** сүздә, сүз белән әйтелгән, телдән әйтелгән; *словесный приказ* — телдән әйтелгән приказ; **2.** сүз...-ы; *словесное творчество* — сүз иҗаты (әдәбият); **3.** *устар.* тел һәм әдәбият...-ы; *словесные науки* — тел һәм әдәбият фәннәре.

**СЛОВЕ'ЧКО** *ср. разг.* — бер сүз, сүз; *ни словечка не скажет* — бер сүз дә әйтмәс.

**СЛОВИ'НКА** *ж.* — словин хатын-кызы.

**СЛОВИ'НСКИЙ** — словин...-ы; *словинский язык* — словин теле.

**СЛОВИ'НЦЫ** *мн.* — словиннар, словин халкы (көнбатыш славяннар тармагыннан бер халык).

**СЛОВИ'ТЬ** *сов. простореч.* — тотып алу, тоту.

**СЛО'ВНИК** *м. спец.* — сүзләр исемлеге (сүзлек төзү өчен).

**СЛО'ВНО** — **1.** шикелле, кебек, бугай; *он словно собирался ехать* — ул китәргә җыенган иде бугай (шикелле); **2.** әйтерсең лә, диярсең.

**СЛО'ВО** I *ср.* — **1.** сүз; **2.** сөйләү, сөйләшү, сөйләү осталыгы; *слово — отличительный признак человека* — сөйләү — кешене аерып тора торган билге; **3.** сүз, вәгъдә; *держаться данного слова* — биргән сүзеңдә тору; **4.** сүз, фикер, карар; *история ещё не сказала своего последнего слова* — тарих әле үзенең соңгы сүзен әйтмәде; **5.** сөйләнү, сүз; *это одни только слова* — сөйләнү генә (сүз генә) бу. ◇ **Без дальних слов** — к. дальний. **Верить на слово** — сүзгә таяну, сүзгә ышану. **Глотать слова** — к. глотать. **Дар слова** — **1.** сөйләү осталыгы, сүзгә осталык; **2.** сөйләү, сөйләшү сәләте. **Держаться на честном слове** *разг. ирон. шутл.* — көчкә-көчкә генә тору, бик ышанычсыз булу. **Другими** или **иными словами** *вводное слово* — башка сүзләр белән әйткәндә, башкача әйткәндә. **Живого слова не услышишь** — бер сүз ишетмәссең. **Крылатые слова** — к. крылатый. **К слову сказать** — сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк; өстәп шуны да әйтергә кирәк. **К слову пришлось** — сүз ара гына әйтелде. **Ловить** (**поймать**) **на слове** — ялгыш әйткән сүзеннән файдалану. **На словах** — **1.** телдән; **2.** сүздә генә. **Не находить слов** — әйтергә сүз таба алмау. **Нет слов** или **слов нет** — һич сүзем юк, бер сүз дә әйтә алмыйм, бәхәсләшеп торасы да юк, чыннан да. **Не хватает слов** — сүз белән генә әйтеп булмый. **Одним словом** — кыскасы, бер сүз белән әйткәндә. **Последнее слово** — соңгы сүз (фәннең, техниканың соңгы сүзе, соңгы казанышлары). **По словам чьим-нибудь**—...-ның сүзе буенча,...-ның әйтүенә караганда. **Слово в слово** — сүзгә сүз. **Слово за слово** или редко **слово за словом** — сүз артыннан сүз, сүз нирә сүз. **С чужих слов** — кеше сүзенә таянып. **Со слов** — ... сөйләүләренә караганда, ... сүзенә таянып.

**СЛО'ВО** II — **1.** *старин.* слово („С" хәрефенең әүвәлге исеме); **2.** *старин.* хәреф, язу билгесе.

**СЛОВОБЛУ'ДИЕ**, **СЛОВОБЛУ'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — буш сүз, сафсата, буш бугазлык.

**СЛОВОИЗВЕРЖЕ'НИЕ** *ср. книж. шутл.* — юк-бар сүз сөйләү, күп һәм юкны лыгырдау, такылдау, сүз ургылышы.

**СЛОВОИЗВИ'ТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — чуарлап сөйләү, матурлап сөйләү.

**СЛОВОИЗМЕНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *лингв.* — сүз төрләнеше; *формы словоизменения* — сүз төрләнеше формалары.

**СЛОВОЛИ'ТНЫЙ** — хәреф кою ...-ы; *словолитное производство* — хәреф кою производствосы.

**СЛОВОЛИ'ТНЯ** *ж.* — хәреф кою мастерское.

**СЛОВОЛИ'ТЧИК** *м. спец.* — хәреф коючы.

**СЛО'ВОМ** *ввод. сл.* — кыскасы, бер сүз белән әйткәндә, нәтиҗәдә; *словом, всё*

*обошлось благополучно* — кыскасы, барысы да уңышлы тәмамланды.

**СЛОВООБРАЗОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *лингв.* — сүз ясалышы, сүзләр ясалышы.

**СЛОВООБРАЗОВА'ТЕЛЬНЫЙ** *лингв.* — сүз ясау ...-ы; (сүз) ясагыч; *словообразовательный аффикс* — сүз ясагыч кушымча.

**СЛОВООХО'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — сүзгә һәвәслелек, сөйләшергә яратучанлык, сүзчәнлек.

**СЛОВООХО'ТЛИВЫЙ** — сүзчән, сөйләшергә яратучан, сүзгә һәвәс, тел бистәсе.

**СЛОВОПРЕ'НИЕ** *ср. книж. устар.* — бәхәс, сүз көрәштерү.

**СЛОВОПРОИЗВО'ДНЫЙ** *лингв.* — 1. (сүз) ясагыч...; *словопроизводный аффикс* — (сүз) ясагыч кушымча; 2. сүз ясалышын күрсәткән; *словопроизводный словарь* — сүз ясалышын күрсәткән сүзлек.

**СЛОВОПРОИЗВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *лингв.* — 1. сүз ясалышы (ясагыч кушымчалар ярдәме белән яңа сүзләр ясалу); 2. *устар.* сүзләрнең килеп чыгышын аңлату, сүзләрнең этимологиясе.

**СЛОВОПРЯ'** *ж. мн.* нет, *разг. шутл.* — к. словопрение.

**СЛОВОРАЗДЕ'Л** *м. лингв.* — ике сүз арасы (сөйләм телендә).

**СЛОВОСОЧЕТА'НИЕ** *ср. лингв.* — сүз тезмәсе.

**СЛОВОСОЧИНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *грам. устар.* — җөмләдә сүзләр бәйләнеше.

**СЛОВОТВО'РЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — яңа сүзләр ясау; яңа сүзләр китереп чыгару.

**СЛОВОТОЛКОВА'НИЕ** *ср. книж.* — сүзләргә аңлатма бирү, сүзләрнең мәгънәсен аңлату.

**СЛОВОТОЛКОВА'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.* — 1. сүзләргә аңлатма бирүче, сүзләрнең мәгънәсен аңлатучы; 2. аңлатмалы сүзлек.

**СЛОВОУДАРЕ'НИЕ** *ср. книж. устар.* — сүз басымы, сүздәге басым.

**СЛОВОУПОТРЕБЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — сүзнең кулланылышы, сүзне куллану, сүзләрне куллану, сүз кулланыш.

**СЛОВЦО'** *ср. разг.* — сүз, бер сүз, бер генә сүз. ◇ **Красное словцо** — к. красный.

**СЛОВЧИ'ТЬ** *сов. просторечн.* — эшне оста йөртеп алу.

**СЛОГ** *м.* — 1. *лингв.* иҗек, сүз иҗеге; 2. *только ед.* стиль, язу стиле, сөйләү стиле.

**СЛОГОВО'Й** *лингв.* — 1. иҗек...-ы; *слоговое письмо* — иҗек язуы (бер билге бер авазны түгел, бөтен бер иҗекне белдергән язу); 2. иҗек ясаучы; *слоговые звуки* — иҗек ясаучы авазлар.

**СЛОГООБРАЗУ'ЮЩИЙ** *лингв.* — к. слоговой 2.

**СЛОГОРАЗДЕ'Л** *м. лингв.* — ике иҗек арасы (бер сүздә).

**СЛОГОУДАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *лингв. устар.* — 1. иҗек басымы; 2. просодия (шигырьдә басымлы һәм басымсыз иҗекләр тәртибе).

**СЛОЕВИ'ЩЕ** *ср. бот.* — катланма (түбән төзелешле үсемлекләрнең, мәсәлән, гөмбәләрнең, мүкләрнең, сүүсемнәрнең, сабакка, тамырга һәм яфракларга бүленми торган гәүдәсе).

**СЛОЕВЦО'ВЫЙ** *бот.* — катланмалы; *слоевцовые растения* — катланмалы үсемлекләр.

**СЛОЁНЫЙ** — катламлы, катлы-катлы (камыр катламнарыннан пешерелгән, мәсәлән, бөккән).

**СЛОЖЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *мат. физ.* җыю, кушу; *правило сложения* — кушу кагыйдәсе; *сложение величин* — зурлыкларны кушу; 2. к. сложить 5, 7; 3. *мат.* кушу гамәле; 4. тән төзелеше; 5. *спец.* матдәнең төзелеше.

**СЛОЖЁННЫЙ** —... тән төзелешле, тән төзелеше ... булган; *он был высокий, пропорционально сложенный мужчина* (Гончаров) — ул озын буйлы, пропорциональ тән төзелешле ир кеше иде.

**СЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — 1. өеп кую; *сложить дрова в сарай* — утынны сарайга өеп кую; 2. салып кую, тутырып кую; *сложить вещи в чемодан* — әйберләрне чемоданга тутырып кую; 3. кушу; *сложить два числа* — ике санны кушу; 4. салу, чыгару; *сложить печку* — мич чыгару; 5. язу, чыгару, иҗат итү; *сложить песню* — җыр чыгару; 6. төшереп (бушатып) өю; *сложить дрова с машины на землю* — утынны машинадан бушатып җиргә өю; 7. өстеннән төшерү (җаваплылыкны, гаепне, бурычны); 8. азат итү, кичерү; *сложить недоимки* — недоимкалардан азат итү; 9 бөкләп кую; *сложить лист пополам* — бер бит кәгазьне урталай бөкләп кую; 10. төреп кую; *сложить платье* — күлмәкне төреп кую. ◇ **Сложа руки сидеть** *разг.* — тик утыру, эшсез утыру, кул кушырып утыру. **Сложить оружие** — үзенне җиңелгән итеп санау, корал ташлау. **Сложить руки** — бернәрсә дә эшләми башлау. **Сложить свою голову** — һәлак булу, үлү.

**СЛОЖИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *разг.* акча салышу (берәр максат белән); 2. килеп чыгу, төзелү; *из кубиков сложился домик* — шакмаклардан кечкенә генә өйчек килеп чыкты; 3. *перен.* формалашу, барлыкка килү, туу; *сложилось социалистическое государство рабочих и крестьян* — эшче һәм крестьяннарның социалистик дәүләте барлыкка килде; 4. үсеп җитү, җитлегү, ныгып җитү, формалашу; *характер его ещё не вполне сложился* — аның характеры әле тулысынча ныгып җитмәгән.

**СЛОЖНОПОДЧИНЁННЫЙ** *грам.* — иярченле кушма; *сложноподчинённое предложение* — иярченле кушма җөмлә.

**СЛОЖНОСОЧИНЁННЫЙ** *грам.* — тезмә кушма; *сложносочинённое предложение* — тезмә кушма җөмлә.

**СЛО'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет — катлаулылык, читенлек, чуалчыклык, авырлык, катлаулы булу, кыен булу. ◇ **В общей сложности** — барлыгы, барысын бергә җыеп әйткәндә, барысын бергә җыеп алганда.

**СЛОЖНОЦВЕ'ТНЫЕ** *мн. в знач. сущ.*— оешма чәчәкләләр (үсемлекләр семьялыгы).

**СЛОЖНОЦВЕ'ТНЫЙ** *бот.*— оешма чәчәкле.

**СЛО'ЖНЫЙ** — 1. катлаулы; *сложное и простое вещество* — катлаулы һәм гади матдә; 2. кушма; *сложное предложение* — кушма җөмлә; 3. читен, кыен, четерекле, буталчык; *сложный вопрос* — кыен мәсьәлә.

**СЛОИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет — катламлы булу, катламлылык, катлы-катлы булу.

**СЛОИ'СТЫЙ** — катламлы, катлы-катлы; *слоистая почва* — катламлы туфрак; *слоистые облака* — катлы-катлы болытлар.

**СЛОИ'ТЬ** *несов. спец.*— (берәр нәрсәдән) катламнар ясау, катлам-катлам итеп өю (хәзерләү).

**СЛОИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. катламлану, катламнарга бүленү; 2. *страд. спец.* катламландырылу.

**СЛОЙ** *м.*— 1. катлам; *верхние слои атмосферы* — атмосфераның югарыгы катламнары; 2. *перен.* масса; *широкие слои населения* — киң (катлау) халык массалары.

**СЛО'ЙКА** *ж.*— 1. к. слоить; 2. *разг.* слойка (катламлы камырдан хәзерләнгән булка).

**СЛО'ЙЧАТЫЙ** — к. слоистый.

**СЛОМ** *м. мн.* нет, *спец.*— 1. к. ломать 1, 3; 2. сыну урыны.

**СЛОМА'ТЬ** *сов.*— 1. сындыру, сындырып төшерү; *сломать сук* — ботакны сындыру; 2. вату; *сломать игрушку* — уенчыкны вату; 3. вату, җимерү; *сломать старый дом* — искергән өйне җимерү; 4. *перен.* җимерү, юкка чыгару, бетерү; *сломать старые обычаи* — иске гореф-гадәтләрне җимерү (юкка чыгару).

**СЛОМА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. сыну; *палка сломалась* — таяк сынды; 2. ватылу; *лёд сломался* — боз ватылды.

**СЛОМИ'ТЬ** *сов.*— 1. сындырып төшерү (сындырып) аудару; *буря сломила старый дуб* — давыл карт имәнне сындырып аударды; 2. *перен.* җиңү, буйсындыру, сындыру, бетерү; *сломить сопротивление врага* — дошманның каршылык күрсәтүен җиңү. ◇ **Сломить голову** *устар.*— башны югалту, һәлак булу. **Сломя голову** *разг.* — җанфәрманга (чабу, йөгерү).

**СЛОМИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. *устар. простореч.* сынып төшү; *сук сломился* — ботак сынып төшкән; 2. *перен.* көчсез булып калу, көчне югалту.

**СЛО'МКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— к. слом 1.

**СЛОН** *м.*— 1. фил; 2. *перен. разг. шутл.* бик зур гәүдәле юан кеше. ◇ **Делать из мухи слона** *разг.*— к. делать. **Слона не приметить** *разг. ирон.*— борын төбендәге бүрәнәне күрмәү.

**СЛОНЁНОК** *м.*— фил баласы.

**СЛО'НИК** *м.* — 1. *разг.* кечкенә фил; 2. *зоол.* коңгыз; *слоник гороховый* — борчак коңгызы.

**СЛОНИ'ХА** *ж.*— ана фил.

**СЛОНО'ВИЙ** *обл. устар.*— к. слоновый.

**СЛОНО'ВЩИК** *м. спец.*— филләр караучы (мәсәлән, зоопаркта), филләр куып баручы, фил йөртүче.

**СЛОНО'ВЫЙ** — фил...-ы; *слоновая кость* — фил сөяге. ◇ **Слоновая бумага** *спец.*— калын кәгазь (рәсем ясау өчен).

**СЛОНЯ'ТЬ** *несов.*: **слонов** или **слоны слонять** *фам. шутл.*— эшсез йөрү, тик йөрү, тырай тибеп йөрү.

**СЛОНЯ'ТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— эшсез йөрү, тик йөрү, арлы-бирле йөрү (нәрсә эшләргә белмичә).

**СЛО'ПАТЬ** *сов. простореч. вульг.*— бүсеп бетерү, тыгынып бетерү, ашап бетерү;

**СЛУГА'** *м.*— 1. *истор.* өй хезмәтчесе; 2. *ритор.* хезмәтче; *депутат — слуга народа* — депутат — халык хезмәтчесе; 3. *презрит.* ялчы.

**СЛУЖА'КА** *м. разг.*— карт эшче, (тырышып) күп хезмәт күрсәткән кеше, хезмәттә батырлык күрсәткән кеше (күбрәк хәрби эштә).

**СЛУЖА'НКА** *ж.*— 1. *устар.* асрау, өйдәге хезмәтче хатын-кыз, өй эшләрен башкаручы хатын-кыз; 2. *перен. ирон.* ялчы; *философия долго была служанкой теологии* — философия озак вакытлар теология ялчысы булып килде.

**СЛУ'ЖАЩИЙ** — 1. хезмәт итүче; *специалист, служащий в тресте* — трестта хезмәт итүче белгеч; 2. хезмәткәр, хезмәтче.

**СЛУ'ЖБА** *ж.*— 1. хезмәт итү; *служба науке* — фәнгә хезмәт итү; 2. хезмәт, эш; *искать службу* — хезмәт эзләү; 3. хезмәт урыны, эшли торган урын; *его служба находится в центре города* — аның эшли торган урыны шәһәр үзәгендә; 4. *спец.* күзәтүче тармак, күзәтүче учреждение; *служба погоды* — һава торышын күзәтү учреждениесе; 5. *только мн. устар.* каралтылар; *дом со службами* — каралтылары булган өй. ◇ **Не в службу, а в дружбу** — к. дружба. **Сослужить службу** — булышлык итү, ярдәм күрсәтү.

**СЛУЖБИ'СТ** *м. разг. устар.*— канцелярия кусесе, формалист.

**СЛУЖЕ'БНЫЙ** — 1. хезмәт...-ы; эш ...-ы; *служебное время* — хезмәт вакыты, эш вакыты; 2. *перен. книж.* ярдәмче, икенче дәрәҗәдәге; *эта гипотеза имела лишь служебное значение* — бу гипотезаның тик ярдәмче әһәмияте генә бар иде; 3. *грам.* ярдәмлек ...; *служебные слова* — ярдәмлек сүзләр.

**СЛУЖИ'ВСКИЙ** *обл.*— к. служивый.

**СЛУЖИ'ВЫЙ** *устар.*— 1. хезмәт...-ы; *дело служивое* — хезмәт эше; 2. *в знач. сущ.* солдат, гаскәри (гадәттә, мөрәҗәгать иткәндә әйтелә).

**СЛУЖИ'ЛЫЙ** *истор.*— йомышлы (Мәскәү Русендә дәүләт хезмәте, гаскәри хезмәт үтәргә тиеш булган кеше).

**СЛУЖИ'ТЕЛЬ** *м.*— 1. *устар.* хезмәтче, ялчы; 2. *офиц. устар.* швейцар, курьер; 3. *книж. ритор.* хезмәт итүче; *служитель науки* — фәнгә хезмәт итүче.

**СЛУЖИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— к. служитель.

**СЛУЖИ'ТЬ** *несов.*— 1. хезмәт итү; *служить народу* — халыкка хезмәт итү; 2. хез-

мәт итү, эшләү; *служить секретарем* — секретарь булып эшләү; 3. хезмәт итү, булып тору; *это служит хорошим примером* — бу яхшы үрнәк булып тора; 4. *церк.* гыйбадәт кылу; 5. ал аякларны күтәреп тору (эт турында). ◇ **Старые сапоги ещё продолжают служить** — иске итегем әле кияргә ярый. **Это пальто служит мне уже пятый год** — бу пальтомны мин бишенче ел киям инде.

**СЛУ'ЗГАТЬ** *сов.*— к. лузгать.

**СЛУКА'ВИТЬ** *сов.*— хәйлә кору, хәйләләп алу, әчкерләләнү.

**СЛУПИ'ТЬ** *сов. простореч.* — к. лупить 2, 5.

**СЛУПИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. лупиться 1.

**СЛУ'ПЛИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. лупить 2.

**СЛУ'ПЛИВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— 1. к. слупиться; 2. *страд.* куптарылу, салдырылу.

**СЛУХ** *м.*— 1. ишетү; *у него хороший слух* — ул яхшы ишетә; 2. *перен. (молва)* хәбәр, кеше сүзе, колактан колакка йөри торган сүз, гайбәт; *ложный слух* — ялган хәбәр, гайбәт; 3. музыкаль сәләт; *у него нет слуха* — аның музыкага сәләте юк. ◇ **Ни слуху ни духу** — тавышы-тыны юк, хәбәре-хәтере юк. **Обратиться в слух** — бик әһәмият бирел тыңлый башлау.

**СЛУ'ХАТЬ** *несов. обл.*— к. слушать 1, 3.

**СЛУХА'Ч** *м. спец.*— 1. радиосигналлар кабул итеп торучы; 2. элемтә челтәрендә (чыбыгы буенча) дошман сөйләшүләрен тыңлап торучы; 3. *только мн.* наушник.

**СЛУХОВО'Й** — ишетү ...-ы, тыңлау ...-ы; *слуховой аппарат* — тыңлау аппараты; *слуховые органы* — ишетү органнары. ◇ **Слуховое окно** — чорма тәрәзәсе.

**СЛУ'ЧАЕМ** *ввод. сл. простореч.*— ничек тә булса, җае чыгып; *ты, случаем, не зайдёшь ко мне?*— син, ничек тә булса, миңа керә алмассыңмы?

**СЛУ'ЧАЙ** *м.*— 1. (көтелмәгән) хәл, вакыйга, очрак; *странный случай* — гаҗәп вакыйга; 2. уңайлы вакыт, уңай, җай; *при случае любит дать понять, что он коллежский регистратор* (Чехов) — җае чыкканда ул үзенең коллежский регистратор икәнлеген белдерергә ярата. ◇ **В случае чего** —...-ган хәлдә, ... була калса; *в случае болезни* — авырган хәлдә, авыру була калса. **На случай** — 1) була калса дип; *взял с собой зонт на случай дождя* — яңгыр була калса дип, үзем белән зонт алдым; 2) *устар.* очраклы рәвештә; *стихи на случай сохранились* (Пушкин) — шигырьләр очраклы рәвештә сакланып калганнар. **По случаю** —...-лыктан, ...-ганга күрә; ...-у сәбәпле; *по случаю дождя экскурсия отменяется* — яңгыр яву сәбәпле экскурсия булмый. **На всякий случай** — кирәк була калса дип. **Упустить случай** — форсаттан файдаланмый калу, форсатны кулдан ычкындыру. **В противном случае** — юкса, югыйсә, алай булмаганда, киресенчә булганда. **Во всяком случае** — һәрхәлдә, ничек кенә булса да.

**СЛУЧА'ЙНО** *нареч.*—1. очраклы рәвештә, көтмәгәндә, һич уйламаганда; 2. *простореч. фам.* түгелме, шикелле, әллә; *вы, случайно, не на собрание идёте?*— сез җыелышка барасыз түгелме? сез җыелышка барасызмы әллә? ◇ **Не случайно** — юкка гына түгел, очраклы гына түгел; *не случайно я говорю об этом* — мин бу турыда юкка гына сөйләмим.

**СЛУЧА'ЙНОСТЬ** *ж.*— 1. *книж.* очраклылык, көтелмәгәнлек; 2. очраклы хәл; *это нельзя считать случайностью* — моны очраклы хәл дип санап булмый.

**СЛУЧА'ЙНЫЙ** — 1. очраклы, очраклы рәвештә булган, көтелмәгән; 2. ара-тирә генә ...-а торган; *случайные встречи* — ара-тирә генә була торган очрашулар.

**СЛУЧА'ТЬ** *несов.*— к. случить.

**СЛУЧА'ТЬСЯ I** *несов.*— к. случиться I.

**СЛУЧА'ТЬСЯ II** *несов.*— 1. к. случиться II; 2. *страд.* йөгертелү, чаптырылу, каплатылу (хайваннар турында).

**СЛУЧИ'ТЬ** *сов.*— 1. *обл. (сблизить)* якынайту, дуслаштыру; 2. *охот.* ау этләрен бергә җыю; 3. йөгертү, чаптыру, каплату (хайваннарны).

**СЛУЧИ'ТЬСЯ I** *сов.*— 1. булу, килеп чыгу; *что случилось?*— ни булды? 2. *разг.* туры килү; *случилось мне как-то ночевать в лесу* — ничектер миңа урманда куnарга туры килде; 3. *разг.* булу, бар булу; *со мной денег не случилось* (Даль) — минем үзем белән (янымда) акчам юк иде.

**СЛУЧИ'ТЬСЯ II** *сов. спец.*— йөгерү, качу, чабу, кушылу (хайваннар турында).

**СЛУ'ЧКА** *ж. мн.* нет — 1. к. случить 3; 2. к. случиться II.

**СЛУ'ЧНИК** *м. спец.*— хайваннар йөгертүче, хайваннар чаптыручы.

**СЛУЧНО'Й, СЛУ'ЧНЫЙ** — йөгертү ...-ы, чаптыру ...-ы; *случный пункт* — хайваннарны йөгертү пункты.

**СЛУ'ШАНИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. тыңлау; *слушание концерта* — концерт тыңлау; 2. карау, тикшерү, тыңлау (судта берәр эшне).

**СЛУ'ШАТЕЛЬ** *м.*, **СЛУ'ШАТЕЛЬНИЦА** *ж.*— 1. тыңлаучы; 2. укучы, студент, лекцияләр тыңлаучы.

**СЛУ'ШАТЕЛЬСКИЙ** *книж.*— тыңлаучылар ...-ы; *слушательский коллектив* — тыңлаучылар коллективы.

**СЛУ'ШАТЬ** *несов.*— 1. тыңлау; 2. (судта) карау, тикшерү, тыңлау; *слушать дело в суде* — эшне судта карау (тикшерү); 3. тыңлау, сүзен тыңлау, колак салу; *не слушайте глупцов* — ахмакларны тыңламагыз, ахмаклар сүзенә колак салмагыз.

**СЛУ'ШАТЬСЯ** *несов.*— 1. тыңлау, колак салу, сүзгә күнү, киңәшне тоту; *слушаться родителей* — ата-аналарны тыңлау, ата-аналарның киңәшен тоту; 2. *страд.* тикшерелү, каралу, тыңлану (судта).

**СЛУШО'К** *м. разг. фам.*— имеш-мимеш, юк-бар сүз, гайбәт, төрле хәбәр.

**СЛЫТЬ** *несов.*— 1. *разг.* даны чыгу, танылу (яхшы яки начар яктан); 2. *просто-*

*реч.* яшәү, бар булу; *пословица такая недаром слывёт* — мондый мәкаль юкка гына яшәми бит.

**СЛЫХА'ТЬ** *несов.*— 1. ишетеп белү, ишетү; 2. *в знач. ввод. сл. простореч.* ахры, бугай, булса кирәк; *ты, слыхать, за новую работу принялся* — син яна эшкә тотынгансың бугай; 3. *в знач. сказ. простореч.* ишетелә; *ничего не слыхать* — бернәрсә дә ишетелми.

**СЛЫ'ХИВАТЬ** *многокр. разг.*— ишеткәләү, ишеткән булу.

**СЛЫ'ХОМ** *нареч.*: **слыхом не слыхать** *просторечю*— беркайчан да ишетмәү, бернәрсә дә билгеле булмау; *он слыхом не слыхал о таких вещах* — мондый әйберләр турында ул беркайчан да ишетмәгән; *о нём слыхом не слыхать* — аның турында бернәрсә дә билгеле түгел.

**СЛЫ'ШАТЬ** *несов.*— 1. ишетү; 2. сизү, тою (мәсәлән, исне); *я не слышала, как укололась* — мин ничек итеп чәнчелгәнемне сизмәгәнмен. ◇ **Не слыша ног** (бежать, мчаться) — бик тиз, ару(ны)-талу(ны) белмичә (йөгерү, чабу).

**СЛЫ'ШАТЬСЯ** *несов.*— 1. ишетелү, ишетелеп тору; 2. сизелү, тоелу.

**СЛЫ'ШИМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— 1. ишетелү, ишетелеш, ишетелү дәрәҗәсе; 2. ишетү мөмкинлеге, ишетелү мөмкинлеге.

**СЛЫ'ШИМЫЙ** *книж.*— ишетелә торган, ишетелерлек.

**СЛЫ'ШНО** *книж.*— 1. *в знач. сказ.* ишетелә; *он сюда хорошо слышно* — моннан яхшы ишетелә; 2. *в знач. сказ.* хәбәрләр бар; *что у вас слышно?*— сездә нинди хәбәрләр бар? 3. *в знач. ввод. сл. разг.* диләр, ахры; *слышно, что ныне будет обильный урожай* — быел бик зур уңыш булыр диләр.

**СЛЫ'ШНЫЙ** — ишетелә торган.

**СЛЫШЬ** *ввод. сл. простореч.*— 1. кара әле, ишетәсеңме; *слышь, он правду говорит* — кара әле, ул дөресен сөйли бит; 2. бугай, ...-дыр ахры; булса кирәк; *он, слышь, придёт* — ул килердер ахры.

**СЛЮБИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.*— 1. яратышу, сөешү; 2. ярату, ошау; *что тебе Литва так слюбилась?* (Пушкин) — нишләп шулай Литваны яраттың?

**СЛЮБЛЯ'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. слюбиться.

**СЛЮДА'** *ж. спец.*— слюда (пыяласыман үтә күренмәле катламлы минерал).

**СЛЮ'ДИСТЫЙ** *мин.*— слюдалы; *слюдистый сланец* — слюдалы сланец.

**СЛЮ'ДОВЫЙ** *спец.*— слюда табу ...-ы; слюда эшкәртү ...-ы; *развитие слюдового дела* — слюда табу эшенең үсеше.

**СЛЮДЯНО'Й** — 1. слюда(дан ясалган); *дом со слюдяным окошком* — слюда(дан ясалган) тәрәзәле өй; 2. слюда чыга торган, слюда эшкәртү ...-ы; *слюдяные районы* — слюда чыга торган районнар.

**СЛЮНА'** *ж.*— төкерек, селәгәй. ◇ **Глотать слюну** *перен. разг.*— төкерек йоту, карын ачкан булу.

**СЛЮ'НИ** *мн.*— к. слюна. ◇ **Распустить слюни** *простореч. фам. презрит.*— мәми авызга әйләнү, җебегән авызга әйләнү.

**СЛЮНИ'ТЬ** *несов.*— 1. төкерекләү; 2. төкерек белән пычрату.

**СЛЮНИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* төкерреккә пычрану; 2 *страд.* төкерекләндерелү.

**СЛЮ'НКА** *ж. разг.*— төкерек, селәгәй. ◇ **Слюнки текут**— авыз сулары килә (берәр тәмле ашны йотардай булып ашарга теләү).

**СЛЮ'ННЫЙ** *анат.*— төкерек ...-ы; селәгәй ...-ы; төкерек бүлеп чыгара торган; *слюнные железы* — төкерек (селәгәй) бизләре.

**СЛЮНООТДЕЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *физиол.*— селәгәй агу, селәгәй килү, төкерек килү, төкерек җыелу.

**СЛЮНООТДЕЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *физиол.* — төкерек җыелу ...-ы; селәгәй килү ...-ы; *слюноотделительный процесс* — селәгәй килү процессы.

**СЛЮНОТЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.*— селәгәй агу, селәгәй килү.

**СЛЮНТЯ'Й** *м.*— 1. *простореч.* селәгәй (кеше); 2. *перен. разг. презрит.* селәгәй, җебегән авыз.

**СЛЮНТЯ'ЙСКИЙ** *разг. фам.*: **слюнтяйский поступок** — җебегән авызлык.

**СЛЮНЯ'ВИТЬ** *несов. разг. фам.* — к. слюнить.

**СЛЮНЯ'ВИТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— 1. төкереккә буялу, төкереккә пычрану; 2. *страд.* төкереккә пычратылу.

**СЛЮНЯ'ВКА** *ж разг. фам.*— 1. күкрәкчә (балалар өчен); 2. *пренебр.* селәгәй бала.

**СЛЮНЯ'ВЫЙ** — селәгәй; *слюнявый мальчишка* — селәгәй малай.

**СЛЯ'БИНГ** *м. тех.*— слябинг (юка корыч табакларны прокатлау станогы).

**СЛЯ'КОТНЫЙ** *разг.* — җепшек карлы, юеш; *слякотная погода* — җепшек карлы һава.

**СЛЯ'КОТЬ** *ж. мн.* нет — 1. җепшек пычрак (яңгыр белән юеш кардан хасил булган пычрак); 2. *разг.* җепшек һава; 3. *перен. разг.* җирәнгеч, кабахәт (кеше яки башка нәрсә турында).

**СЛЯ'МЗИТЬ** *сов. простореч.* — сыпырту, чәлү, урлау.

**СЛЯ'ПАТЬ** *сов. простореч. обл.* — сылап кую, әвәләп кую, әвәләп ясау.

**СЛЯ'ПСИТЬ** *сов. простореч. вульг.* — к. слямзить.

**СМА'ЗАТЬ** *сов.* —1. майлау, сөртү, сөртеп алу; *смазать колёса дёгтем* — тәгәрмәчләрне дегет белән майлау; *смазать горло глицерином* — бугазга глицерин сөртү; 2. *перен. устар.* майлау (взятка бирү); *смазать чиновника* — чиновникны майлау (взятка бирү); 3. *перен. разг. неодобр.* аныклыгын бетерү, үткенлеген (кискенлеген) югалту; *смазать вопрос* — мәсьәләнең аныклыгын бетерү; 4. *перен. простореч. вульг.* бик каты итеп китереп сугу, чәпәү, кундыру, тондыру.

**СМА'ЗАТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. (үзеңнең берәр җиреңә) сөртү, сөртенү; *смазаться иодом* — иод сөртү (үзеңнең берәр җиреңә);

2. (буяу) җәелеп пычратып бетерү; *вся краска смазалась* — барлык буяу җәелеп пычратып бетергән.

**СМА'ЗКА** *ж.* — 1. майлау, май сөртү; 2. май, майлау әйбере; *смазка для колёс* — тәгәрмәч мае.

**СМАЗЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг. фам.* — тышкы матурлык, тышкы чибәрлек, сөйкемлелек.

**СМАЗЛИ'ВЫЙ** *разг. фам.* — төскә матур, сөйкемле, чибәр.

**СМАЗНО'Й** *спец.* — майлана торган (товар).

**СМА'ЗОЧНОЕ** *ср. в знач. сущ.* — майлау материалы; *трактористы сэкономили много смазочного* — трактористлар күп кенә майлау материалына экономия ясадылар.

**СМА'ЗОЧНЫЙ** *спец.* — майлау ...-ы; *смазочный материал* — майлау материалы.

**СМА'ЗЧИК** *м.*, **СМА'ЗЧИЦА** *ж. спец.* — майлаучы, май сөртүче; *смазчик железнодорожных вагонов* — тимер юл вагоннарын майлаучы.

**СМА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. смазать.

**СМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. смазаться; 2. *страд.* май сөртелү.

**СМАЗЬ** *ж. спец.* — май; *смазь для машин* — машина мае.

**СМА'ИВАТЬ** *несов. обл.* — к. смаять.

**СМА'ИВАТЬСЯ** *несов. обл.* — 1. к. смаяться; 2. *страд.* ялыктырылу, интектерелү, хәлдән тайдырылу, алҗытылу.

**СМАК** *м. мн.* нет — 1. тәм, тәмлелек, тәмлелек тойгысы; *есть что-н. со смаком* — берәр нәрсәне тәмен белеп ашау; *в этих яблоках особый смак* — бу алмаларның үзенә бер төрле тәме бар; 2. *перен.* тәм, рәхәт, рәхәтлек; *рассказывать что-н. со смаком* — берәр нәрсәне тәмләп сөйләү; 3. *перен.* мәгънә, кызыклык, үткенлек; *вы не поняли весь смак этого рассказа* — сез бу хикәянең бөтен тәмен (кызыклыгын) сизмәдегез.

**СМАКЛА'ЧИТЬ** *сов. простореч. фам. устар.* — 1. маклерлык итеп рәтләү; 2. маклерлык итеп булдыру; *смаклачить себе домик* — маклерлык итеп үзенә өй булдыру.

**СМАКОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *разг. фам.* тәмен белеп ашау (эчү); *смаковать каждый глоток* — һәр йотымның тәмен белеп эчү; 2. *перен. разг. фам.* тәмен белеп (табып) эшләү, тәмләп эшләү; *смаковать новость* — яңа хәбәрне тәмләп сөйләү; 3. *обл.* тәмен татып карау, тәмен тою.

**СМА'ЛЕЦ** *м. обл.* — эретелгән туң май.

**СМА'ЛУ** *нареч. простореч.* — яшьтән үк, кече яшьтән үк.

**СМА'ЛЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. смолчать.

**СМА'ЛЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. молоть 1.

**СМА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. смолоться; 2. *разг.* тарттырылу (онга).

**СМА'ЛЬТА** *ж. мн.* нет, *спец.* — 1. смальта (ачык зәңгәр буяу); 2. төрле төстәге ясалма ташлар.

**СМА'НИВАТЬ** *несов. разг.* — к. сманить.

**СМАНИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. кызыктырып җыю (мәсәлән, кошларны җим сибеп); 2. *перен.* кызыктырып күчерү; *сманить на другое место* — кызыктырып икенче урынга күчерү.

**СМАРА'ГД** *м. устар.* — зөбәрҗәт (асылташ).

**СМАРА'ГДОВЫЙ** *устар.* — зөбәрҗәт (тән эшләнгән); *смарагдовый перстень* — зөбәрҗәт кашлы йөзек.

**СМАРА'ТЬ** *сов. простореч.* — бозу, сөртү (язганны).

**СМА'РИВАТЬ** *несов. разг.* — к. сморить.

**СМА'РИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. смориться.

**СМА'РЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. смарать.

**СМА'РЫВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — бозылу, сөртелү (язылган нәрсә).

**СМАСТА'ЧИТЬ** *сов. простореч. фам.* — к. мастачить.

**СМАСТЕРИ'ТЬ** *сов. разг.* — к. мастерить.

**СМА'ТРИВАТЬ** *многокр. разг.* — караштыргалау, ара-тирә карап кую, ара-тирә күз салу.

**СМА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. смотать.

**СМА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. смотаться.

**СМАХА'ТЬ** *сов. простореч. шутл.* — (тиз генә) йөгереп барып килү.

**СМА'ХИВАТЬ** *несов.* — 1. к. смахнуть; 2. *разг. фам.* бераз охшау, хәтерләтү (берәүне яки берәр нәрсәне).

**СМА'ХУ** *нареч. разг.* — 1. бөтен көченә, кизәнеп; *ударить смаху* — кизәнеп сугып җибәрү; 2. *перен. фам.* тиз генә, уйлапнитеп тормыйча; *сделать что-н. смаху* — берәр нәрсәне тиз генә эшләп ташлау.

**СМА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. смочить.

**СМА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — әзрәк юешләтелү, бераз чылатылу.

**СМА'ЧНО** *нареч. разг. фам.* — тәмен табып, ләззәтләнеп, төчеләнеп, тәмләп, тәмен белеп; *смачно рассказывать что-н.* — төчеләнеп берәр нәрсә сөйләү.

**СМА'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг. фам.* — тәмлелек.

**СМА'ЧНЫЙ** *разг. фам.* — 1. тәмле; *смачный кусок* — тәмле кисәк; 2. бик каты, төчеләнеп (эшләнгән); *смачная ругань* — төчеләнеп (бик каты) сүгенү.

**СМА'ЯТЬ** *сов. обл.* — хәлдән тайдыру, алҗытып бетерү, җәфалап бетерү, азаплап бетерү, йөдәтеп бетерү.

**СМА'ЯТЬСЯ** *сов. обл.* — хәлдән таю, алҗып бету, җәфаланып бетү, йөдәп бетү.

**СМЕЖА'ТЬСЯ** *несов. книж. поэт.* — к. смежиться.

**СМЕЖИ'ТЬ** *сов. книж. поэт.* — йому, ябу (күбесенчә күзләр турында әйтелә).

**СМЕЖИ'ТЬСЯ** *сов. книж. поэт.* — йомылу, ябылу.

**СМЕ'ЖНИК** *м.* — 1. *устар.* күрше, чиктәш (җирләре янәшә булган кешеләр); 2. ярдәмче производство (төп производствога детальләр, төрле кисәкләр хәзерләүче производство).

**СМЕ'ЖНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. янәшәлек, ызандашлык; *смежность участков* — участокларның янәшәлеге; 2. чиктәшлек, бер-беренә нык бәйләнеш.

**СМЕ'ЖНЫЙ** *книж.* — янәшә, күрше, чиктәш, ызандаш.

**СМЕКА'ЛИСТЫЙ** *простореч. фам.* — бик зирәк, тиз төшенүчән, зиһенле, эшне белеп йөртүчән.

**СМЕКА'ЛКА** *ж. мн.* нет, *простореч.* — зиһенлелек, зирәклек, тиз төшенүчәнлек, сизү, тиз төшенү.

**СМЕКА'ТЬ** *несов. разг. фам.* — тиз төшенү, сизү, аңлап алу.

**СМЕКНУ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — аңлап алу, төшенеп алу, сизеп алу.

**СМЕЛЕ'ТЬ** *несов.* — кыюлану, батырая төшү.

**СМЕ'ЛО** *нареч.* — 1. кыю, батыр, житез; 2. *разг.* һичбер авырлыксыз, җиңел генә, бик иркен, бик җиңел; *здесь может смело поместиться триста человек* — биредә бик иркен өч йөз кеше урнаша ала.

**СМЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — батырлык, кыюлык, гайрәтлелек, йөрәклелек.

**СМЕ'ЛЫЙ** — 1. кыю, батыр, гайрәтле, йөрәкле; 2. *перен.* әдәпсез, оятсыз; *смелая шутка* — оятсыз шаяру.

**СМЕЛЬЧА'К** *м. разг.* — кыю кеше, йөрәкле кеше, батыр кеше.

**СМЕ'НА** *ж.* — 1. к. сменить; 2. к. смениться; 3. смена; *вечерняя смена* — кичке смена; *утренняя смена* — иртәнге смена; 4. алмаш; *готовить себе смену* — үзеңә алмаш хәзерләү.

**СМЕ'НИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. сменять II.

**СМЕ'НИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. сменяться.

**СМЕНИ'ТЬ** *сов.* — алмаштыру, алыштыру.

**СМЕНИ'ТЬСЯ** *сов.* — алмашу, алмашыну.

**СМЕ'ННИК** *м.*, **СМЕННИ'ЦА** *ж.* — алмаштыручы, алмашка килүче.

**СМЕ'ННЫЙ** — 1. алмашка килүче, алмаштыручы; *сменный рабочий* — алмаштыручы эшче; 2. сменалап эшләнә торган; *сменная работа* — сменалап эшләнә торган эш; 3. смена ...-ы; *сменное собрание в цехе* — цехта смена җыелышы.

**СМЕ'НЩИК** *м.*, **СМЕ'НЩИЦА** *ж.* — к. сменник.

**СМЕНЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — алмашынучанлык, алмашлы булу, алмашынучан булу.

**СМЕНЯ'ЕМЫЙ** — 1. алмаштырырлык, алмаштырыла торган; *сменяемые части машины* — машинаның алмаштырыла торган кисәкләре; 2. алмашына торган; *часто сменяемые начальники* — еш алмашына торган башлыклар.

**СМЕНЯ'ТЬ** I *сов. разг.* — алмашу, алмаштыру.

**СМЕНЯ'ТЬ** II *несов.* — к. сменить.

**СМЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. смениться; 2. *страд.* алмаштырылу.

**СМЕРД** *м. истор.* — 1. игенче крестьян (борынгы Россиядә); 2. кара халык, түбән катлау кешесе.

**СМЕРДЕ'ТЬ** *несов.* — ис чыгару, аңкыту, сасыту.

**СМЕРЁТУШКА** *ж. нар.-поэт обл.* — үлем.

**СМЕРЗА'ТЬ** *несов. обл.* — к. смерзнуть.

**СМЕРЗА'ТЬСЯ** *несов.* — к. смерзнуться.

**СМЁРЗЛЫЙ** *простореч. обл.* — боз булып каткан, туңган.

**СМЁРЗНУТЬ** *сов. обл.* — 1. туңу, өшү, күшегү, кату; 2. к. смёрзнуться.

**СМЁРЗНУТЬСЯ** *сов.* — туңып бергә кату, туңып кату, туңып укмашу.

**СМЕ'РИТЬ** *сов.* — үлчәү, үлчәп алу, үлчәп чыгу. ◇ **Смерить взглядом** или **глазами** — баштанаяк карап чыгу (берәүне), күз йөртеп чыгу.

**СМЕ'РИТЬСЯ** *сов. простореч.* — үлчәнү (буеңны яки көчеңне) үлчәп карау.

**СМЕРКА'ТЬСЯ** *несов.* — к. смеркнуться.

**СМЕРКНУ'ТЬСЯ** *сов.* — караңгы төшү, эңгер-меңгер вакыт житү, кич булу.

**СМЕ'РОК** *м. спец.* — үлчәү (берәр кешедән яки әйбердән алынган үлчәү, берәр кешенең яки әйбернең аерым өлешләренең күләме күрсәтелгән язма).

**СМЕРТЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — үтерерлек булу, үләрлек булу, үтергеч булу.

**СМЕРТЕ'ЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. үтерә торган, үтерерлек, үтергеч; *смертельный яд* — үтергеч агу; 2. *перен.* һәлак иткеч; *смертельный кризис* — һәлак иткеч кризис; 3. *перен.* үтә аяусыз, үтә кискен, чиксез каты; *смертельная борьба с врагом* — дошман белән аяусыз көрәш; 4. *перен.* чиксез тирән, чиксез зур; *смертельная ненависть* — чиксез тирән нәфрәт; 5. *перен.* килешү мөмкин булмаган, мәңгелек, килешмәслек; *смертельный враг* — килешү мөмкин булмаган дошман; 6. *перен.* бик нык, бик каты; *смертельная усталость* — бик нык арыганлык.

**СМЕ'РТНИК** *м.* — 1. үлемгә хөкем ителгән кеше; 2. *книж. редко* тиздән үләчәк кеше.

**СМЕ'РТНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — үлемгә хөкем ителгәнлек, үлем җәзасына хөкем ителгәнлек.

**СМЕ'РТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — үлүчелек, үлүчеләр саны, үлем саны.

**СМЕ'РТНЫЙ** — 1. үлә торган, үләчәк; 2. үлем ...-ы; *смертный одр* — үлем түшәге; *смертная казнь* — үлем җәзасы; 3. *перен.* к. смертельный 3, 4, 6.

**СМЕРТОНО'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет — үтерерлек булу, үтергеч булу.

**СМЕРТОНО'СНЫЙ** *книж.* — үтергеч, үтерерлек, үтерә торган; һәлакәтле.

**СМЕРТОУБИ'ЙСТВО** *ср. простореч.* — үтерү, сугышканда үтерү.

**СМЕРТЬ** *ж.* — 1. үлем, әҗәл; 2. *перен.* һәлакәт, үлем; *социализм несёт смерть капиталистическому миру* — социализм капиталистик дөньяга үлем китерә (һәлакәт алып килә); 3. *в знач. нареч.* бик, бик нык, чиктән тыш, үлеп; *смерть как хочется пить* — бик нык эчәсем килә, үлеп эчәсем килә. ◇ **До смерти** *разг.* — бик нык, үлеп; *до смерти спать хочется* —

бик нык йоклыйсы килә. **При смерти** — үлем хәлендә.

**СМЕРЧ** *м.* — өермә.

**СМЕРЧЕВО'Й** — өермә ...-ы; *смерчевой столб* — өермә баганасы.

**СМЕ'РЩИК** *м.*, **СМЕ'РЩИЦА** *ж. спец.* — үлчәүче, үлчәп торучы.

**СМЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. смерить.

**СМЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. смериться.

**СМЕСИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — болгаткыч (изгеч) машина.

**СМЕСИ'ТЕЛЬНЫЙ** *тех.* — болгаткыч..., болгата торган; *смесительная машина* — болгата торган машина.

**СМЕСИ'ТЬ** *сов.* — к. месить.

**СМЕСИ'ТЬСЯ** *сов. просторeч.* — яхшы изелү, басылу, басылып җитү (мәсәлән, камыр).

**СМЕСТИ'** *сов.* — **1.** себереп ташлау, себереп чистарту, себереп төшерү, сыпырып төшерү; **2.** себереп өю; **3.** *перен. ритор.* себереп ташлау, юк итү; *смести с лица земли врагов революции* — революция дошманнарын җир йөзеннән себереп ташлау.

**СМЕСТИ'СЬ** *сов.* — себереп ташлану, юкка чыгу.

**СМЕСТИ'ТЬ** *сов.* — **1.** *офиц.* төшерү (урыныннан), хезмәтеннән чыгару; **2.** *книж.* күчерү, урынын үзгәртү; *сместить точку наблюдения* — күзәтү ноктасын күчерү; **3.** *перен.* үзгәртү; *сместить развитие фабулы* — фабуланың үсешен үзгәртү.

**СМЕСТИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** күчү, урыныннан күчү; **2.** *перен.* үзгәрү, торышы үзгәрү, юнәлеше үзгәрү.

**СМЕСЬ** *ж.* — катнашма.

**СМЕ'ТА** I *ж.* — смета (алдан чамаланган кирәчәк керемнәр һәм тотылачак чыгымнар исәбе).

**СМЕ'ТА** II *ж. устар. просторeч.* — фикер йөртү, уйлау, фараз итү.

**СМЕТА'НА** *ж. мн.* нет — (әче) каймак.

**СМЕТА'ННИК** *м.*, **СМЕТА'ННИЦА** *ж.* — **1.** *разг. фам.* (әче) каймак ашарга яратучы; **2.** (әче) каймак савыты.

**СМЕТА'ННЫЙ** — (әче) каймак ...-ы; (әче) каймактан ясалган; *сметанное масло* — (әче) каймак мае, (әче) каймактан язылган май.

**СМЕТА'ТЬ** I *несов.* — к. смести.

**СМЕТА'ТЬ** II *сов.* — күкләп чыгу, күкләү, типчеп чыгу, типчү (киемне).

**СМЕТА'ТЬ** III *сов.* — **1.** өю; салу; *сметать стог* — кибән (богыл) салу; **2.** *обл.* көрәп ташлау, көрәп төшерү; *сметать снег с крыши* — өй түбәсеннән карны көрәп төшерү.

**СМЕТА'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. сместись; **2.** *страд.* себереп (сыпырып) ташлану, себереп өелү, себереп төшерелү.

**СМЁТКА** *ж. мн.* нет — зирәклек, зиһенлелек, тапкырлык.

**СМЁТКИ** *только мн. обл.* — себереп өелгән чүп.

**СМЕ'ТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тапкырлык, зирәклек, зиһенлелек.

**СМЕ'ТЛИВЫЙ** — тапкыр, зирәк, зиһенле.

**СМЕТНУ'ТЬ** *однокр. обл.* — көрәп ташлау, көрәп төшерү.

**СМЕ'ТНЫЙ** — сметага кертелгән, сметада каралган; *сметные ассигнования* — сметада каралган ассигнованиеләр.

**СМЁТЫВАТЬ** I *несов. порт.* — күкләп чыгу, типчеп чыгу.

**СМЁТЫВАТЬ** II *несов.* — к. сметать III.

**СМЁТЫВАТЬСЯ** I *несов. порт.* — күкләп чыгылу, типчеп чыгылу.

**СМЁТЫВАТЬСЯ** II *несов. страд.* — **1.** өелү, салыну (мәсәлән, кибән); **2.** көрәп ташлану, көрәп төшерелү (мәсәлән, кар).

**СМЕТЬ** *несов.* — батырчылык итү, кыюлык итү, кыюлык җитү. ◇ **Не смей(те) трогать** — кагыласы булма(гыз). **Как смел сказать** — моны әйтергә ничек телең барды. **Как смеет** — ничек кулы (яки теле) бара, ничек булдыра ала, ничек кыюлыгы җитә.

**СМЕХ** *м. мн.* нет — көлү тавышы, көлгән тавыш, көлү, көлке. ◇ **Без смеху** *разг.* — һичбер көлкесез, һичбер шаяртусыз. **Не до смеху** — көлке түгел. **Поднять на смех** — көлү, мәсхәрәләү. **Покатиться со смеху** — к. покатиться. **Смеха ради** — көлке өчен, шаярту өчен, көлеп кенә.

**СМЕХОТА'** *ж. мн.* нет, *фам.* — көлке.

**СМЕХОТВО'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — көлке булу, көлкелек.

**СМЕХОТВО'РНЫЙ** *пренебр.* — көлке, көлдерерлек.

**СМЕ'ШАННЫЙ** — **1.** катыштырылган,... кушылган; *вино, смешанное с водой* — су белән катыштырылган (су кушылган) аракы; **2.** катнашма, катнашкан; *смешанные породы* — катнашма токымнар; **3.** катнаш; *смешанная комиссия* — катнаш комиссия.

**СМЕША'ТЬ** *сов.* — **1.** катнаштыру; кушу; *смешать вино с водой* — аракыны су белән катнаштыру, аракыга су кушу; **2.** болгату; *смешать кашу с маслом* — боткага май салып болгату; **3.** бутау, бутап бетерү; *смешать два понятия* — ике төшенчәне бутау; *кто-то смешал все мои бумаги* — кемдер минем кәгазьләремне бутап бетергән.

**СМЕША'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** катнашу, катышу, аралашу; *маргарин смешался с маслом* — маргарин май белән катнашкан; **2.** *перен.* буталу, буталып бетү; *смешались все понятия* — барлык төшенчәләр буталып беткән; **3.** аптырап калу; *ученик смешался* — укучы аптырап калды.

**СМЕ'ШИВАТЬ** *несов.* — к. смешать.

**СМЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. смешаться и смеситься; **2.** *страд.* болгатылу, болгатып бетерелү; катнаштырылу, катыштырылу, аралаштырылу.

**СМЕШИ'ТЬ** *несов.* — көлдерү.

**СМЕШЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — көлүчәнлек, көләргә яратучанлык.

**СМЕШЛИ'ВЫЙ** — көлүчән, көләргә яратучан.

**СМЕШНО'** **1.** *нареч.* — көлке итеп; *смешно рассказывать* — көлке итеп сөйләү; **2.** *безл. в знач. сказ.* көлке.

**СМЕШНО'Й** — **1.** көлке, көләрлек; *смешной анекдот* — көлке анекдот; **2.** *перен.*

ахмак, акылга сыймаган, көлке; *смешные требования* — акылга сыймаган (көлке) таләпләр.

**СМЕШО'К** *м. разг.* — **1.** аз гына (сизелер-сизелмәс кенә) көлеп кую, кеткелдәп кую; **2.** *только мн. фам.* көлеп карау, мыскыл итеп көлү.

**СМЕЩА'ТЬ** *несов.* — к. сместить.

**СМЕЩА'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** *книж.* к. сместиться; **2.** *страд.* төшерелү (урыныннан); күчерелү, үзгәртелү.

**СМЕЯ'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** көлү, көлешү; **2.** кешедән көлү; **3.** *перен.* шаяру, шаярып сөйләү, көлеп сөйләү; *не верь ему, он смеётся* — ышанма аңа, ул шаярып (көлеп) сөйли.

**СМИ'ГИВАТЬСЯ** *несов.* — к. смигнуться.

**СМИГНУ'ТЬ** *сов. разг.* — күз кысып кую, күз(не) ачып йому.

**СМИГНУ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — күз кысышу, күз кысышып ризалыкны белдерү.

**СМИ'ЛОВАТЬСЯ** *сов. книж. устар.* — җәлләү, кызгану, шәфкате килү, миһербаны килү.

**СМИЛОВА'ТЬСЯ** *сов. обл.* — яратышу, бер-береңне ярату, сөешү, мәхәббәт тотышу.

**СМИНА'ТЬ** *несов.* — к. смять.

**СМИНА'ТЬСЯ** *несов.* — к. смяться.

**СМИРЁНА** *м.* и *ж. простореч.* — к. смиренник, смиренница.

**СМИРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — **1.** к. смирить; **2.** тыйнаклык, басынкылык, буйсынучанлык.

**СМИРЕ'ННИК** *м.*, **СМИРЕ'ННИЦА** *ж. разг. чаще ирон.* — тыйнак, басынкы, буйсынучан, баш иючән, юаш (кеше).

**СМИРЕ'ННИЧАТЬ** *несов. разг. ирон.* — баш игән булу, буйсынган булу, тыйнаклык күрсәтеп маташу, буйсынган булып кылану.

**СМИРЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — тыйнаклык, басынкылык, буйсынучанлык, юашлык.

**СМИРЕ'ННЫЙ** — басынкы, тыйнак, юаш.

**СМИРИ'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.* — буйсындыручы, тыючы, баш идерүче.

**СМИРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *устар.* — басынкыландыра торган, буйсындыра торган, акылга утырта торган; *смирительные меры* — басынкыландыра торган чаралар. ◇ **Смирительный дом** — юләрләр йорты.

**СМИРИ'ТЬ** *сов.* — буйсындыру, тыю, баш идерү; бастыру, тыйнакландыру.

**СМИРИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — буйсыну, баш ию, баш бирү, тыелу, басынкылану, тыйнаклану, юашлану.

**СМИ'РНА** *ж. истор.* — хуш исле сумала.

**СМИ'РНО** *нареч.* — тик кенә, тыныч, юаш кына. ◇ **Смирно!** *воен.* — смирно! (Сафта үрә катып торырга кушылган команда.)

**СМИ'РНЫЙ** — **1.** тыныч, юаш (кеше); **2.** *старин.* кайгылы, кайгы белдерә торган; матәм...-ы; *смирная одежда* — матәм киеме.

**СМИРЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. смирить.

**СМИРЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — к. смириться.

**СМЛА'ДА** *нареч. книж. устар.* — к. смолоду.

**СМОКА'ТЬ** *несов. простореч.* — смокнуть.

**СМО'КВА** *ж.* — инжир (җимеш).

**СМО'КИНГ** *м.* — смокинг (күкрәк турысы киң ачылып тора торган кара пиджак).

**СМО'КНУТЬ** *сов. простореч.* — юешләнү, җебү, дымлану.

**СМОКО'ВНИЦА** *ж. бот.* — инжир агачы.

**СМОЛА'** *ж. спец.* — сумала, чәер, сагыз.

**СМОЛА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. молотить.

**СМОЛА'ЧИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сугылу (ашлык).

**СМОЛЕВА'ТЫЙ** *спец.* — чәерле, сумалалы, сагызлы.

**СМОЛЕВО'Й** *спец.* — сумалалы, сумала сеңдерелгән; *смолевой канат* — сумала сеңдерелгән аркан.

**СМОЛИ'ЛЬНЫЙ** *тех.* — сумалалый торган, сумалалау...-ы; *смолильные приспособления* — сумалалау җайланмалары.

**СМОЛИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — сумалалаучы (эшче).

**СМОЛИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет — сумалалы булу, сумаласы күп булу.

**СМОЛИ'СТЫЙ** — сумалалы, сумалага бай.

**СМОЛИ'ТЬ** *несов.* — сумалалау, сумала сеңдерү.

**СМОЛИ'ТЬСЯ** *несов.* — сумалалану.

**СМОЛКА'ТЬ** *несов.* — к. смолкнуть.

**СМО'ЛКНУТЬ** *сов.* — **1.** тынып калу, басылу, тынычлану; **2.** *разг.* сөйләүдән туктау, тынып калу.

**СМОЛОВА'Р** *м. спец.* — к. смолокур.

**СМОЛОВА'РЕННЫЙ** *спец.* — к. смолокуренный.

**СМОЛОВА'РНЯ** *ж. спец.* — к. смолокурня.

**СМОЛОГО'Н** *м. спец.* — сумала кайнатучы, сумала куучы.

**СМО'ЛОДУ** *нареч. разг.* — яшьтән үк, яшь вакыттан бирле.

**СМОЛОКУ'Р** *м. спец.* — сумала кайнатучы, сумала куучы.

**СМОЛОКУРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — сумала кайнату, сумала куу.

**СМОЛОКУ'РЕННЫЙ** *спец.* — сумала кайнату...-ы; сумала куу...-ы; *смолокуренное производство* — сумала куу производствосы.

**СМОЛОКУ'РНЯ** *ж. спец.* — сумала кайнату урыны, сумала куу урыны.

**СМОЛОТИ'ТЬ** *сов.* — сугу (ашлыкны).

**СМОЛО'ТЬ** *сов.* — тарту; *смолоть кофе* — кофе тарту.

**СМОЛО'ТЬСЯ** *сов.* — тартылу (кофе, ашлык һ. б.).

**СМОЛЧА'ТЬ** *сов. разг.* — эндәшми калу, берни дә әйтмәү, җавап бирмәү.

**СМОЛЬ** *ж.*: **чёрный, как смоль** — чем-кара (чәчләр, күзләр турында).

**СМО'ЛЬНЫЙ** *устар.* — сумала ...-ы; *смольная бочка* — сумала мичкәсе.

**СМОЛЯ'К** *м. спец.* — (күп яткан) сумалалы торф, чәерле торф.

**СМОЛЯНО'Й** — сумала ...-ы; *смоляной*

*запах* — сумала исе; ***смоляная бочка*** — сумала мичкәсе.

**СМОНТИ'РОВАТЬ** *сов. спец.*— к. монтировать.

**СМОРГНУ'ТЬ** *сов.*— күз йому; ***он соврёт и глазом не сморгнёт*** — ул күзен дә йоммас, алдар.

**СМОРИ'ТЬ** *сов. разг.*— хәлдән тайдыру, арыту, алжыту, алжытып бетерү.

**СМОРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ару, хәлдән таю, алжып бетү.

**СМОРКА'ТЬ** *несов. разг.*: **сморкать нос** — борын сеңгерү.

**СМОРКА'ТЬСЯ** *несов.*— борын сеңгерү.

**СМОРКНУ'ТЬ** *сов. простореч.*— к. сморкать.

**СМОРКНУ'ТЬСЯ** *однокр.*— к. сморкаться.

**СМОРО'ДА** *ж. мн.* нет, *обл* — к. смородина.

**СМОРО'ДИНА** *ж. мн.* нет — карлыган.

**СМОРО'ДИНКА** *ж. мн.* нет — 1. к. смородина; 2. карлыган бөртеге, бер бөртек карлыган.

**СМОРО'ДИННИК** *м. спец.* — карлыган куаклыгы, карлыганлык.

**СМОРО'ДИННЫЙ** — 1. карлыган...-ы; ***смородинный лист*** — карлыган яфрагы; 2. карлыган...-ы; карлыганнан ясалган; ***смородинное варенье*** — карлыган вареньесы.

**СМОРО'ДИНОВКА** *ж.*— карлыган төнәтмәсе.

**СМОРО'ДИНОВЫЙ** — к. смородинный.

**СМОРО'ДОВЫЙ** *обл.*— к. смородинный.

**СМОРО'ЗИТЬ** *сов. разг. фам.*— киләкмәгән сүз әйтү, ахмак сүз ычкындыру, юкны әйтеп ташлау, ахмак сүз әйтеп кую.

**СМОРЧКО'ВЫЙ** — 1. кәҗә гөмбәсе...-ы; ***сморчковый вкус*** — кәҗә гөмбәсе тәме; 2. кәҗә гөмбәсеннән ясалган; ***сморчковый соус*** — кәҗә гөмбәсеннән ясалган соус.

**СМОРЧО'К** *м.*— 1. кәҗә гөмбәсе; 2. *перен простореч. презрит.* бетерешкән кеше, зәгыйфь кеше.

**СМО'РЩЕННЫЙ** — 1. җыерчыкланган, җыерылган; 2. җыерчыклы; ***сморщенный лоб*** — җыерчыклы маңгай; 3. *разг. фам.* бөрешкән, җыерчыкланып беткән; ***сморщенная старушка*** — бөрешкән карчык.

**СМО'РЩИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. морщить.

**СМО'РЩИВАТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. морщиться 2, 3.

**СМО'РЩИТЬ** *сов.*— к. морщить.

**СМО'РЩИТЬСЯ** *сов.*— к. морщиться 2, 3.

**СМОТА'ТЬ** *сов.*— 1. чорнау, чорнап кую; 2. сүтү, сүтеп алу (чорнаганны). ◇ **Смотать удочки** *перен.*— тиз генә китеп бару, шылу, таю.

**СМОТА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. чорналу; 2. сүтелү (чорнаган әйбер); 3. *перен. простореч. вульг.* китеп югалу, таю, шылу, тиз генә китеп бару; 4. *простореч. вульг.*— тиз генә барып кайту.

**СМОТР** *м. офиц.*— смотр үткәрү, күздән үткәрү; ***смотр войскам*** — гаскәрләргә смотр үткәрү.

**СМОТРЕ'ТЬ** *несов.*— 1. карау; ***смотреть в окно*** — тәрәзәдән карау; ***окна смотрят во двор*** — тәрәзәләре ишек алдына карый (ягъни ишек алды ягына); 2. күз йөртеп чыгу, (укып) танышып чыгу; ***смотреть рукопись*** — кулъязмага күз йөртеп чыгу; 3. *воен.* смотр үткәрү, смотр ясау; ***смотреть войска*** — гаскәрләргә смотр ясау; 4. *простореч.* күз йөртеп эзләү; ***смотреть кого-н в толпе*** — халык төркеме арасыннан берәр кешене күз йөртеп эзләү; 5. *разг.* күзәтү, күз-колак булу; ***смотреть за детьми*** — балаларны күзәтү, балаларга күз-колак булу; ***смотреть за порядком*** — тәртип күзәтү; 6. *разг.* үрнәк алу, карау; ***смотреть на старших*** — олылардан үрнәк алу; ***не смотрите на лентяев*** — ялкаулардан үрнәк алмагыз, ялкауларга карамагыз; 7. ... дип карау,... чыгып карау, буларак карау, ...-ча бәя бирү; ***смотреть на события глазами историка*** — вакыйгаларга тарихчы буларак бәя бирү; 8. *перен.* (*виднеться*) күренеп тору, күренү. ◇ **Смотреть молодцом** — батыр кыяфәтле булу, үзенне батырларча тоту. **Смотреть орлом**— горур кыяфәттә (кыяфәтле) булу. **Смотреть волком, зверем** — усал (шәфкатьсез) кыяфәттә (кыяфәтле) булу. **Смотри(те)** *повел. накл.*— кара(гыз) аны; ***смотри, не упади*** — кара аны, егылма. **Смотря где идти** — кайдан барыргадыр бит, кайдан барасың бит. **Смотря какой человек** — нинди кешедер бит, кем булуына карап. **Смотря по** — ...-га карап; **одеваться смотря по погоде** — һаваның нинди булуына карап киенү. **Смотреть в глаза** *кому* — тәлинкә тоту, ялагайлану. **Смотреть в глаза** *чему книж.*— 1. күзенә карау, (авыр моментта) салкын канлылык күрсәтү, нык тору; ***смотреть в глаза опасности*** — куркынычның күзенә карау, куркыныч булганда салкын канлылык күрсәтү; 2. дөрес карау, дөрес бәя бирү; ***смотреть в глаза фактам*** — фактларга дөрес карау. **Смотреть в оба** — к. оба.

**СМОТРЕ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. карану (мәсәлән, көзгедән); 2. *страд.* каралу; ***пьеса смотрится с большим интересом*** — пьеса зур кызыксыну белән карала.

**СМОТРИ'НЫ** *обл.*— кыз багу, кәләш сайлау йоласы (борынгыда).

**СМОТРИ'ТЕЛЬ** *м.*, **СМОТРИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. доревол.*— күзәтеп торучы, тәртип саклап торучы (иске мәктәпләрдә, төрмәләрдә, тимер юлларында), смотритель.

**СМОТРИ'ТЕЛЬША** *ж. доревол.*— смотритель хатыны.

**СМОТРОВО'Й, СМО'ТРОВЫЙ, СМОТРО'ВЫЙ** — 1. смотр...-ы; ***смотровая комиссия*** — смотр комиссиясе; 2. *спец.* күзәтү ...-ы; күзәтеп тору ...-ы; ***смотровая щель в танке*** — танкның күзәтү ярыгы.

**СМОТРО'К** *м. обл.*— карап торучы, күзәтүче.

**СМО'ТЧИК** *м.*, **СМО'ТЧИЦА** *ж. спец.* — чорнаучы, чорнап торучы (эшче).

**СМОЧИ'ТЬ** *сов.*— юешләү, чылату.

**СМОЧЬ** *сов.*— булдыру, ...-а алу; ***не смог понять*** — аңлый алмадым.

**СМОШЕ'ННИЧАТЬ** *сов. разг.*— к. мошенничать.

**СМРА'Д** *м. мн.* нет — 1. сасы ис; 2. сөрем, төтен.

**СМРА'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. ритор.*— сасылык, сасы исле булу.

**СМРА'ДНЫЙ** — 1. сасы исле; 2. төтенле, сөремле; *от лесных пожаров стоял смрадный туман* — урман янудан сөремле томан җәелгән иде.

**СМУГЛЕ'ТЬ** *несов.*— кара тутлылану, кара кучкыллану.

**СМУГЛОЛИ'ЦЫЙ** — кара тутлы, кара кучкыл йөзле; *смуглолицый мальчик* — кара кучкыл йөзле малай.

**СМУ'ГЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — кара кучкыллык, кара тутлылык.

**СМУ'ГЛЫЙ** — кара тутлы, кара кучкыл тәнле, кара тәнле.

**СМУГЛЯ'ВЫЙ** *обл.*— к. смуглый.

**СМУГЛЯ'НКА** *ж. разг.*— кара тутлы, кара кучкыл тәнле (кыз, хатын).

**СМУДРИ'ТЬ** *сов. разг.*— (акыл саткан булып) берәр ахмак эш эшләү, ахмак сүз әйтү.

**СМУДРОВА'ТЬ** *сов. простореч.*— к. смудрить.

**СМУ'РЫЙ** *обл. нар.-поэт.*— кара көрән, коңгырт көрән, кара соры, коңгырт соры.

**СМУ'ТА** *ж.*— 1. фетнә, чуалыш, тәртипсезлек, 2. коткы, ызгыш, талаш; *сеять смуту* — коткы тарату.

**СМУТИ'ТЬ** *сов.*— 1. оялту, кызарту, каушату; 2. борчу, борчу тудыру, тынычлыкны бозу; 3. *устар.* коткы тарату, чуалту, фетнә чыгару.

**СМУТИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. оялу, каушап калу; 2. *устар.* баш күтәрү, фетнә чыгару.

**СМУ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. фетнәлелек, гаугалылык; 2. *перен.* анык түгеллек, анык булмаганлык, тоныклык; 3. *перен.* тынычсызлык, борчулылык.

**СМУ'ТНЫЙ** — 1. фетнәле, чуалышлы, гаугалы; 2. *перен.* анык булмаган, тонык, тәртипсез; *смутные воспоминания* — анык булмаган истәлекләр; 3. *перен. книж.* борчулы, тынычсыз; *смутное состояние* — тынычсыз хәл (халәт).

**СМУТЬЯ'Н** *м.*, **СМУТЬЯ'НКА** *ж. разг. фам. неодобр.*— коткы салучы, фетнәче, коткы таратучы, ара бозыштыручы, гауга чыгаручы, җәнҗал куптаручы.

**СМУТЬЯ'НИТЬ** *несов. разг. фам. неодобр.* — котырту, ара бозу, коткы тарату, гауга чыгару.

**СМУ'ЧИВАТЬ** *несов. обл.*— к. смучить.

**СМУ'ЧИТЬ** *сов. обл.*— газаплау, җәфалау, җәфалап бетерү, интектереп бетерү.

**СМУ'ШЕК** *м.*, **СМУ'ШКА** *ж. обл.*— бәрән тиресе, илтер.

**СМУ'ШКОВЫЙ** *спец.*— илтер..., бәрән тиресеннән эшләнгән (тегелгән); *смушковая шапка* — илтер бүрек (бәрән тиресеннән тегелгән бүрек).

**СМУЩА'ТЬ** *несов.*— к. смутить.

**СМУЩА'ТЬСЯ** *несов.*— к. смутиться.

**СМУЩЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — оялу, каушап калу, уңайсызлану.

**СМЫВА'ЛЬНЫЙ** *спец.*— юып чистарту ...-ы; юу...-ы; *смывальный чан* — юу чаны.

**СМЫВА'ТЬ** *несов.*— к. смыть.

**СМЫВА'ТЬСЯ** *несов.*— юылу, юып чистартылу.

**СМЫ'ВКИ** *ед.* нет, *обл. спец.*— юылдык (берәр нәрсәне юуудан калган калдыклар)

**СМЫВНО'Й** — 1. юып чистарту ...-ы; юу ...-ы; юа торган; *смывной чан* — юу чаны; 2. су юып алып киткән, дулкын юып алып киткән; *смывной песок* — дулкын юып алып киткән ком.

**СМЫ'ВЩИК** *м. спец.*— юучы, юу хезмәтен үтәүче (эшче).

**СМЫКА'ТЬ** *несов.*— к. сомкнуть.

**СМЫКА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. сомкнуться; 2. *страд.* тоташтырылу.

**СМЫ'ЛКИ** *ед.* нет, *простореч.* — (юылып бетмәгән) сабын калдыклары.

**СМЫСЛ** *м.*— 1. мәгънә; *прямой смысл слова* — сүзнең туры мәгънәсе; 2. максат, нигез; *смысл жизни* — тормышның максаты; тормыштан максат; 3. *разг.* файда, мәгънә; *мне нет смысла переходить на другую работу* — миңа башка эшкә күчүдән файда юк; 4. *книж.* акыл; *здравый смысл* — саф акыл, сәламәт акыл. ◇ **В полном смысле слова** *разг.*— тулысынча, тәмам, бөтенләй; *он в полном смысле слова сумасшедший* — ул бөтенләй акылдан язган кеше. **В смысле** *чего* — ... яктан алганда, ... яктан караганда.

**СМЫ'СЛИТЬ** *несов. разг.*— төшенү, аңлау, белү; *ведь он ничего не смыслит* — ул бит бернәрсә дә белми.

**СМЫСЛОВО'Й** *лингв.*— мәгънә...-ы; *смысловые оттенки* — мәгънә төсмерләре.

**СМЫТЬ** *сов.*— 1. юып төшерү (бетерү), юып алу, юып чистарту, юып китәрү; *смыть грязь* — пычракны юып төшерү (бетерү); 2. *перен.* (*искупить что-н.*) юу, аклану, өстеңнән төшерү; 3. юып алып китү, агызып алып китү; *водой смыло лодку* — су көймәне агызып алып киткән; 4. *перен. простореч. вульг.* чәлү, урлау; 5. *воен.* кырып бетерү, юкка чыгару; *смыть пулемётами наступающие цепи противника* — һөҗүм итеп килүче дошман рәтләрен пулемёт белән кырып бетерү.

**СМЫ'ТЬСЯ** *сов.*—1. юылу, юылып бетү, юылып чистару; *эти пятна не смоются* — бу таплар юылып бетмәс; 2. *перен. простореч. вульг.*— юк булу, таю, шылу, сызу; *смылся из комнаты* — бүлмәдән чыгып тайды.

**СМЫ'ЧКА** *ж.*—1. *спец.* к. сомкнуть 1, сомкнуться 1; 2. тоташкан урын, берекән урын; 3. *перен.* элемтә, берекәнлек.

**СМЫЧКО'ВЫЙ** — смычоклы, смычок...-ы; *скрипка—смычковый инструмент* —скрипка — смычоклы инструмент.

**СМЫ'ЧНЫЙ** *лингв.*— йомык; *смычные согласные* — йомык тартыклар, йомык тартык авазлар.

**СМЫЧО'К** *м.*— смычок. скрипка смычогы.

**СМЫШЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — зирәклек, аңлылык, тапкырлык.

**СМЫШЛЁНЫЙ** — зирәк, аңлы, төшенүчән, тапкыр.
**СМЫШЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — уйлап эзләнү.
**СМЯГЧА'ТЬ** *несов.* — к. смягчить.
**СМЯГЧА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. смягчиться; 2. *страд.* йомшартылу, җиңеләйтелү.
**СМЯГЧА'ЮЩИЙ** — 1. җиңеләйтә торган; *смягчающие вину обстоятельства* — гаепне җиңеләйтә торган шартлар (хәлләр); 2. *мед.* йомшарта торган; *смягчающие средства* — йомшарта торган дарулар (чаралар).
**СМЯГЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. смягчить, смягчиться; 2. *лингв.* нечкәрү, нечкәртелү (аваз).
**СМЯГЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *мед.* — йомшарта торган, йомшарткыч; *смягчительная мазь* — йомшарткыч май.
**СМЯГЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. йомшарту; *смягчить кожу выделкой* — күнне эшкәртеп йомшарту; 2. *перен.* җиңеләйтү; *смягчить вину* — гаебен җиңеләйтү; *смягчить боль* — авыртуын җиңеләйтү; 3. *перен.* шәфкатен кузгату, миһербанын кузгату, мәрхәмәт уяту; 4. *лингв.* нечкәртү; *звук „и" в русском языке смягчает предшествующий согласный* — рус телендә „и" авазы үзеннән алда килгән тартык авазны нечкәртә.
**СМЯГЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. йомшару; *кожа смягчилась* — күн йомшарды; 2. *перен.* җиңеләю, йомшару; *боль смягчилась* — авырту җиңеләйде; 3. *перен.* басылу, йомшару; *гнев смягчился* — ачу басылды; 4. *перен.* шәфкате килү, шәфкатьләләнү, миһербаны килү, йомшару; *отец смягчился* — әти йомшарды; 5. *лингв.* нечкәрү; *в слове „кость" „с" перед „т" смягчилось* — „кость" сүзендә „с" авазы „т" алдыннан килеп нечкәргән.
**СМЯКА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. смякнуть.
**СМЯ'КНУТЬ** *сов. простореч.* — 1. йомшару, җебү, изерәү, изелү; 2. *перен. шутл.* кыюлыгын югалту, изерәп төшү, җебегән авызга әйләнү.
**СМЯТЕ'НИЕ** *ср. книжн.* — 1. бик нык каушау, каушап калу, аптырап калу; 2. паника, курку; *вызвать смятение в рядах противника* — дошман сафларында паника тудыру.
**СМЯТЕ'ННОСТЬ, СМЯТЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книжн. устар.* — бик нык каушаганлык, аптыраш.
**СМЯТЕ'ННЫЙ** и **СМЯТЁННЫЙ** *книжн. устар.* — бик нык каушаган, чиксез борчылган, чиксез борчылулы.
**СМЯТЬ** *сов.* — 1. таушалдыру, йомарландыру, бөрештерү; 2. изү; *смять глину* — балчык изү; 3. *перен. воен.* таркату, туздыру, качарга мәҗбүр итү (дошман көчләрен).
**СМЯ'ТЬСЯ** *сов.* — таушалу, йомарлану, бөрешү.
**СНАБДЕВА'ТЬ** *несов. устар.* — к. снабжать.
**СНАБДИ'ТЬ** *сов.* — 1. тәэмин итү, булдыру; *снабдить учреждение топливом* — учреждениене ягулык белән тәэмин итү; *снабдить всех работников инструкцией* — барлык работниклар өчен инструкция булдыру; 2. өстәү; *снабдить книгу примечаниями* — китапка искәрмәләр өстәү.
**СНАБДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — тәэмин ителү.
**СНАБЖА'ТЕЛЬ** *м. устар.* — тәэмин итүче.
**СНАБЖА'ТЬ** *несов.* — к. снабдить.
**СНАБЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. (товарларны һ. б.) алу; тәэмин ителү; *магазины снабжаются из своих баз* — магазиннар товарларны үз базаларыннан алалар; 2. *страд.* тәэмин ителү.
**СНАБЖЕ'НЕЦ** *м.* — тәэмин итү органында эшләүче, тәэмин итү белгече.
**СНАБЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. снабдить; 2. *офиц.* барлык кирәк-яраклар, барлык азык-төлек һ. б.; *пищевое снабжение* — барлык азык-төлек (барлык продуктлар); *артиллерийское снабжение* — барлык артиллерия кирәк-яраклары.
**СНАБЖЕ'НЧЕСКИЙ** — тәэмин итү...-ы; *снабженческий аппарат* — тәэмин итү аппараты.
**СНА'ДОБЬЕ** *ср.* — 1. *устар.* шифалы үләннәрдән һәм матдәләрдән ясалган дару; 2. *разг. ирон.* дару; 3. *разг. шутл. устар.* аш тәмләткеч.
**СНА'ЙПЕР** *м.* — снайпер, мәргән (бик төз атучы).
**СНА'ЙПЕРСКИЙ** *воен. спорт.* — снайпер...-ы; снайперлар...-ы;снайперларча; *снайперская стрельба* — снайпер атуы, снайперларча ату.
**СНА'ЙПИНГ** *м. мн.* нет, *воен. спорт.* — бик төз ату, снайперларча ату.
**СНАРУ'ЖИ** *нареч.* — тышкы яктан, тыштан.
**СНАРЯ'Д** *м.* — 1. *устар.* к. снарядить и снарядиться; 2. *воен.* снаряд, туп ядрәсе; 3. кирәк-яраклар, кораллар, инструментлар, снаряд; *столярный снаряд* — столярлык кирәк-яраклары; *гимнастический снаряд* — гимнастика снаряды.
**СНАРЯДИ'ТЬ** *сов.* — кирәк-ярагын хәзерләп кую, житештереп кую; кирәк-ярак белән тәэмин итү, җиһазландыру.
**СНАРЯДИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — кирәк-яракны хәзерләп кую, житештереп кую, хәзерләнеп кую, җыену.
**СНАРЯ'ДНЫЙ** — 1. снаряд...-ы; *снарядный завод* — снаряд заводы; 2. *спорт.* снарядта башкарыла торган; *снарядная гимнастика* — снарядта (турникта һ. б.) башкарыла торган гимнастика (күнегүләре).
**СНАРЯ'ДОВЫЙ** *спорт.* — снарядта..., снарядта башкарыла торган; *снарядовые упражнения* — снарядта (турникта һ. б.) башкарыла торган күнегүләр.
**СНАРЯЖА'ТЬ** *несов.* — к. снарядить.
**СНАРЯЖА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. снарядиться; 2. *страд.* кирәк-яраклар белән тәэмин ителү, җиһазландырылу (мәсәлән, судно).
**СНАРЯЖЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. снарядить и снарядиться; 2. кирәк-яраклар (мәсәлән, гаскәр кирәк-яраклары, юл һ. б. өчен кирәк-яраклар).
**СНАСТИ'ТЬ** *несов. простореч. спец.* —

жиһазландыру. кирәк-ярагын җитештереп, хәзерләп кую.

**СНАСТИ'ТЬСЯ** *несов. простореч. спец.*— җиһазландырылу, кирәк-ярагы җитештерелү, хәзерләп куелу.

**СНАСТЬ** *ж.*—1. җиһаз, кирәк-ярак, берәр эш өчен кирәкле кораллар; 2. *мор.* судно баулары.

**СНАЧА'ЛА** *нареч.*—1. (иң) элек, башта, (иң) әүвәл; *сначала подумай, потом отвечай* — башта уйла, аннары җавап бир; 2. баштан, яңабаштан, яңадан; *начать сначала* — яңабаштан башлау.

**СНА'ШИВАТЬ** I *несов.*— киеп туздырып бетерү.

**СНА'ШИВАТЬ** II *несов.*— к. сносить III.

**СНА'ШИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. сноситься I.

**СНЕГ** *м.*—кар. ◇ **Как снег на голову** — кинәт, көтмәгәндә.

**СНЕГИ'РЬ** *м. зоол.*— карабүрек (кош).

**СНЕГОБОРЬБА'** *ж. мн.* нет — кар белән көрәш (мәсәлән, тимер юлларда).

**СНЕГОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. снегозадержание.

**СНЕГОВО'Й**—1. кар...-ы; *снеговой покров* — кар капламы; 2. кар белән капланган, карлы; *снеговые горы* — кар белән капланган таулар, карлы таулар; 3. кар(дан ясалган); *снеговая кукла* — кар курчак.

**СНЕГОЗАДЕРЖА'НИЕ** *ср. мн.* нет — кар тоту.

**СНЕГОЛО'М** *м. обл.*— кар сындырган, кар басып аударган яшь агачлар.

**СНЕГООБРА'ЗНЫЙ** *книж.*— карсыман, карга охшаган, кар төсле.

**СНЕГООЧИСТИ'ТЕЛЬ** *м. спец.*— кар арчыгыч, кардан чистарткыч.

**СНЕГООЧИСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.*— кар арчыгыч..., кардан чистарткыч..., кар арчый торган, кардан чистарта торган.

**СНЕГООЧИ'СТКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— кар арчу, кардан чистарту.

**СНЕГОПА'Д** *м. мн.* нет — кар төшү, кар яву (күп булып).

**СНЕГОПА'Х** *м. с.-х.*— кар сөргеч (карны тоту өчен сөреп китереп бер җиргә өя торган җайланма).

**СНЕГОТА'ЯЛКА** *ж. спец.*— кар эреткеч, кар эретү аппараты.

**СНЕГОТА'ЯНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*—1. кар эрү; 2. кар эретү.

**СНЕГОУБО'РОЧНЫЙ** — кар җыю...-ы, кар чистарту...-ы, кар арчу...-ы; *снегоуборочная машина* — кар арчу машинасы.

**СНЕГОХО'Д** *м. спец.*— к. аэросани.

**СНЕГУ'РКА, СНЕГУ'РОЧКА** *ж.*—1. каркыз, кардан булган кыз (әкияттә); 2. снегурочка (конькиның — тимераякның бер төре).

**СНЕДА'ТЬ** *несов.*—1. *обл.* ашау, ашауга тоту; 2. *книж.* газаплау, җәфалау.

**СНЕ'ДНЫЙ** *книж. устар. обл.*— ашый торган, ашарга ярый торган, ашарлык.

**СНЕДЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар. обл.* — аш, ашамлык, азык.

**СНЕЖИ'НА** *ж. разг.*— эре кар бөртеге.

**СНЕЖИ'НКА** *ж.*— кар бөртеге.

**СНЕЖИ'СТЫЙ** *обл.*— карлы, күп карлы; *снежистая зима* — күп карлы кыш.

**СНЕЖИ'ТЬ** *несов. обл.*—1. карлату; *вытирай ноги, не снежи пол* — сөрт аякларыңны, идәнне карлатма; 2. кар яву, кар төшү; *то дождит, то снежит* — я яңгыр ява, я кар ява.

**СНЕЖНИ'ЦА** *ж.*—1. кардан күзләр камашу, күз чагылу; 2. *только ед. обл.* кар суы; 3. *обл.* кар суы җыелган урын.

**СНЕ'ЖНО** *в знач. сказ. разг.*— кар бик күп.

**СНЕ'ЖНЫЙ**—1. кар...-ы; *снежный свет* — кар яктысы; 2. кар белән капланган; *снежные крыши* — кар белән капланган өй түбәләре; 3. карлы, күп карлы; *снежная зима* — күп карлы кыш; 4. карсыман, кардай; *снежная белизна* — кардай аклык. ◇ **Снежная слепота** — к. снежница 1.

**СНЕЖО'К** *м. разг.*—1. кар; 2. кар кисәге, йомарланган кар; *играть в снежки* — кар атышып уйнау.

**СНЕЖУРА'** *ж. мн.* нет, *обл.*— карлы су, сулы кар.

**СНЕСТИ'** *сов.*—1. илтү, илтеп тапшыру, илтеп салу; *снести письмо на почту* — хатны почтага илтеп салу; 2. төшерү, төшереп кую; *снести вещи в подвал* — әйберләрне подвалга төшерү; 3. алып китү; *река снесла плоты вниз по течению* — елга салларны агым белән алып киткән; 4. кубарып ату, каерып ату; *буря снесла крышу* — давыл түбәне каерып аткан; 5. вату, җимерү, юк иту; *снести сарай* — сарайны җимерү; 6. чабып өзү, кисеп төшерү; *снести голову саблей* — башны кылыч белән кисеп төшерү; 7. читкә чыгару; *судно снесло течением* — агым судноны читкә чыгарды; 8. ташып өемгә өю; 9. йомырка салу; 10. чыдап калу, түзеп калу; *снести обиду* — хурлыкка түзеп калу; 11. күтәреп алып китү; *поднять подыму, а не снесу* (Даль)— күтәрүен күтәрермен, әмма алып китә алмам.

**СНЕСТИ'СЬ** *сов.*—1. бәйләнешкә керү, хәбәрләшү, язышу; 2. йомырка салу.

**СНЕТКО'ВЫЙ** — күл чабагы...-ы; *снетковая уха* — күл чабагы шулпасы.

**СНЕТО'К** *м.*— күл чабагы.

**СНИЖА'ТЬ** *несов.*— к. снизить.

**СНИЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. снизиться; 2. *страд.* түбәнәйтелү, төшерелү, киметелү.

**СНИЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. снизить; 2. к. снизиться.

**СНИЗА'ТЬ** *сов.*— тезү; *снизать бусы* — сәйләннәр тезү.

**СНИ'ЗИТЬ** *сов.*— 1. түбәнәйтү, түбәнәйтә төшү; 2. *перен.* киметү, төшерү; *снизить цены* — бәяләрне төшерү; 3. *перен. разг.* йомшарту; *снизить тон*—тонны йомшарту; 4. (хезмәттә түбән урынга) төшерү; 5. *перен. лит.* гадиләштерү, тупасландыру (стильне).

**СНИ'ЗИТЬСЯ** *сов.*— 1. түбәнәю, түбәнәя төшү; 2. *перен.* киму, төшү; *цены снизились* — бәяләр төшкән; *требования снизились* — таләпләр кимегән; 3. *перен.* йомшару, басылу; *тон снизился* — тон йомшарды.

**СНИЗОЙТИ'** *сов.*— 1. *устар.* түбәнгә төшү; 2. *устар. ирон.* илтифат итү, игътибар итү, колак салу; *снизойти на просьбу* — үтенечкә колак салу.

**СНИ'ЗУ** *нареч.*— 1. астан, астыннан, аскы яктан, түбәннән; 2. *перен.* халык тарафыннан, киң масса тарафыннан; *прислушиваться к критике снизу* — киң масса тарафыннан ясалган тәнкыйтькә колак салу; 3. *простореч.* төбеннән; *снизу дерева* — агач төбеннән. ◇ **Снизу доверху** — к. сверху донизу.

**СНИКА'ТЬ** *несов. разг.*— к. сникнуть.

**СНИ'КНУТЬ** *сов. разг.*— 1. бөгелү, салынып төшү, бөрешү; *ветки сникли* — ботаклар салынып төшкән; 2. боегу, кәеф китү; *она вдруг как-то сникла* (Лесков)— ул ничектер кинәт боегып китте.

**СНИМА'ТЬ** *несов.*— к. снять.

**СНИМА'ТЬСЯ** *несов.*— к. сняться.

**СНИ'МКА** *ж. простореч.*— 1. к. снимать 1; 2. *спец.* бетергеч, резинка.

**СНИ'МКИ** *только мн. обл.*— куе сөт өсте, каймак.

**СНИ'МОК** *м.*— 1. рәсем, фотокарточка; 2. күчермә.

**СНИ'МЩИК** *м.*, **СНИ'МЩИЦА** *ж. простореч. спец.*— рәсемгә төшерүче, рәсемгә алучы.

**СНИСКА'ТЬ** *сов. книж.*— 1. табу; *трудами снискать пропитание* — эшләп азык табу; 2. казану, ирешү, булдыру; *снискать себе славу* — дан казану, данлыклы булуга ирешү, данлы булу.

**СНИСХОДИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — түбәнчелеклелек, түбәнчелекле булу, юл куючанлык, рәхимлелек, мәрхәмәтлелек.

**СНИСХОДИ'ТЕЛЬНЫЙ** — түбәнчелекле, юл куючан, үтенечне үтәүчән; мәрхәмәт күрсәтүчән; *снисходительный тон* — юл куючан тон, мәрхәмәт күрсәтүчән тон.

**СНИСХОДИ'ТЬ** *несов. книж.*— к. снизойти.

**СНИСХОЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *устар.* к. снизойти; 2. йомшак мөгамәлә, мәрхәмәт; *иметь снисхождение к кому-н.*— берәр кешегә карата йомшак мөгамәләдә булу.

**СНИТО'К** *м.*— к. снеток.

**СНИ'ТЬСЯ** *несов.*— төшкә керү, төштә күрү.

**СНОБ** *м. книж. презрит.*— сноб, кием калыбы (купшы киенеп үзен әллә кемгә санап йөрүче кеше).

**СНОБИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж. презрит.*— снобизм (борын күтәреп үзен әллә кемгә санап йөрү).

**СНО'ВА** *нареч.*— яңадан, яңабаштан, тагы бер кат.

**СНОВА'ЛКА** *ж. спец.*— 1. буй сару машинасы, буй сару станогы; 2. буй саручы (буй сару станогында эшләүче хатын-кыз).

**СНОВА'ЛЬНЫЙ** *спец.*— буй сару...-ы; *сновальная машина* — буй сару машинасы.

**СНОВА'ЛЬЩИК** *м.*, **СНОВА'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*— буй саручы.

**СНОВА'ТЬ** *несов.*— 1. буй сару; 2. *перен. разг.* киләп сару, әрле-бирле йөрү.

**СНОВА'ТЬСЯ** *несов.*— буй сарылу.

**СНОВИДЕ'НИЕ** *ср. книж.*— төш, төш күрү.

**СНОВИ'ДЕЦ** *м. книж. устар.*— „чын" төш күрүче.

**СНО'ВКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— 1. буй сару; 2. сарылган буй.

**СНОГСШИБА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— искиткеч булу, шаккатыргыч булу.

**СНОГСШИБА'ТЕЛЬНЫЙ** *разг. шутл.*— искиткеч, шаккатыргыч.

**СНОП** *м.*— көлтә.

**СНОПО'ВКА** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— көлтә бәйләү.

**СНОПОВЯ'З** *м. с.-х. обл.*— көлтә бәйләүче.

**СНОПОВЯЗА'ЛКА** *ж. с.-х.*— көлтә бәйләгеч (ура һәм көлтә бәйләп бара торган машина).

**СНОПОВЯЗА'ЛЬНЫЙ** *с.-х.*— көлтә бәйләү...-ы; *сноповязальная машина* — көлтә бәйләү машинасы.

**СНОПООБРА'ЗНЫЙ** *книж.*— көлтәсыман, көлтәгә охшаган.

**СНОПОПОДАВА'ТЕЛЬ** *м. с.-х.*— көлтә биргеч (ашлык сугу машинасында көлтә биреп тора торган җайланма).

**СНОРО'ВИСТЫЙ** *разг.*— оста, булдыклы, житез.

**СНОРОВИ'ТЬ** *сов. обл.*— тию, эләгү.

**СНОРО'ВКА** *ж. мн.* нет, *разг.*— осталык, булдыклылык, житезлек.

**СНОС** I *м. мн.* нет — сүтү, вату, җимерү; *дом назначен на снос* — өй сүтеп алуга билгеләнгән.

**СНОС** II: **сносу нет** — бик нык, тузмый, тузуны белми (өс һәм аяк киемнәре турында); **не знать сносу** — озакка чыдау, тузмау (кием турында).

**СНОС** III: **на сносях** *разг.*— тиздән тудырырга тиеш (көмәнле хатын турында).

**СНОСИ'ТЬ** I *сов. разг.*— киеп туздыру.

**СНОСИ'ТЬ** II *сов. разг.*— алып барып кайту; *сносить грудного ребенка к доктору* — имчәк баласын докторга алып барып кайту. ◇ **Ему не сносить головы** *разг.*— ул башын югалтачак, муенын сындырачак, яхшылыкка түгел.

**СНОСИ'ТЬ** III *несов.*— к. снести 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 10.

**СНОСИ'ТЬСЯ** I *сов. разг.*— киелеп тузу, тузып бетү (кием).

**СНОСИ'ТЬСЯ** II *несов.*— 1. к. снестись 1; 2. *страд.* илтеп куелу, илтеп салыну, илтеп тапшырылу; 3. *страд.* сүтелү, сүтеп алыну (мәсәлән, өй).

**СНО'СКА** *ж.*— сноска (китап битенең астына төшереп бирелгән искәрмә).

**СНО'СНЫЙ** — 1. сүтеләчәк; *сносный дом* — сүтеләчәк өй; 2. чыдарлык, түзәрлек; *сносные боли* — түзәрлек авыртулар; 3. канәгатьләнерлек, уртача, ярарлык; *сносные условия* — канәгатьләнерлек шартлар.

**СНО'СЧИК** *м. спец.*— ташучы, ташып бер җиргә өюче (эшче).

**СНОТВО'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. йоклата торган булу, йокы китерә торган булу;

2. *перен.* эчпошыргыч булу, ялыктыргыч булу, йоклата торган булу.

**СНОТВО'РНЫЙ** — 1. *мед.* йоклата торган, йокы китергеч, йокы китерә торган; 2. *перен.* йокы китергеч, ялыктыргыч (эчпошыргыч); *снотворный рассказ* — йокы китерә торган (эчпошыргыч) хикәя.

**СНОТОЛКОВА'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.*— 1. төш юраучы; 2. төш юрау китабы, тәгъбирнамә.

**СНОТОЛКОВА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.*— төш юрау...-ы; *снотолковательная книга* — төш юрау китабы (тәгъбирнамә).

**СНОХА'** *ж.*— килен, җиңги.

**СНОШЕ'НИЕ** *ср. книж.*— бәйләнеш, багланыш, якынлык, йөрешү. ◇ **Половое сношение** — якынлык кылу, женси мөнәсәбәт.

**СНЯТЬ** *сов.* — 1. алу, алып кую; *снять картину со стены* — картинаны стенадан алып кую; *снять сливки с молока* — сөт өстен алу; *снять крышку с кастрюли* — кастрюльнең капкачын алу; 2. төшерү, күтәреп төшерү; *снять ребёнка со стула* — баланы урындыктан төшерү; 3. салу, салып кую; *снять пальто* — пальтоны салу; 4. салдыру, салдырып алу; *снять шубу с гостя* — кунакның тунын салдыру; 5. *перен. разг. (уничтожить)* бетерү, юкка чыгару; 6. кагып төшерү; *снять пылинку с рукава* — тузан бөртеген (тузанны) җиңнән кагып төшерү; 7. җыю, җыеп алу; *снять урожай* — уңышны җыеп алу; 8. кисү, кисеп алу, кисеп төшерү, кисеп кыскарту; *снять голову* — башын кисү; *снять с доски на полпальца* — тактаны ярты бармак буе кисеп кыскарту; 9. алу, алып җибәрү; *снять с фронта на отдых уставшие части* — арыган частьларны фронттан алып ял итәргә җибәрү; 10. алу, юк итү; *снять вражеского часового* — дошманның часовоен юк итү; 11. *филос. книж.* бетерү, юкка чыгару; *снять противоречие* — каршылыкны бетерү; *его предложение сняло все спорные вопросы* — аның тәкъдиме барлык бәхәсле мәсьәләләрне юкка чыгарды; 12. *перен. офиц.* алу, чыгару, төшерү; *снять с работы* — эшеннән чыгару; *снять с учёта* — учёттан төшерү; 13. *перен.* кире алу, төшерү, алу; *снять своё предложение* — үз тәкъдимеңне кире алу; *снять с очереди* — чираттан төшерү; 14. алу; *снять мерку с чего-нибудь* — берәр нәрсәнең үлчәвен алу; *снять допрос* — сорау алу; 15. төшерү, төшереп алу; *снять план участка* — участокның планын төшереп алу; *снять кого-нибудь фотоаппаратом* — берәр кешене фотоаппарат белән төшереп алу; 16. (акча түләп вакытлыча файдалануга) алу; *снять дачу* — (вакытлыча файдалануга) дача алу. ◇ **Как рукой сняло** *простореч.*— кул белән алып ташлагандай булды; эзе дә калмады (кайгы-хәсрәт, авырту турында). **Снять пароход с мели** — сайлыкка утырган пароходны тартып чыгару. **Снять обвинение** — гаепне алып ташлау, аклау. **Снять копию** — копиясен алу, күчермәсен алу.

**СНЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. алыну, чыгу; *крышка легко снялась* — капкач ансат алынды; 2. рәсемгә төшү; *сняться группой* — группа белән рәсемгә төшү. ◇ **Сняться с якоря** — якорь(не) күтәрү, кузгалып китү, юлга чыгу. **Сняться с дрейфа** — дрейфтан кузгалып китү. **Отряд снялся** — отряд кузгалып китте.

**СО** *предлог* — к. с I, с II, с III.

**СОА ВТОР** *м. книж.* — автордаш, әсәр язуда катнашучы (бер үк әсәрне язуда катнашкан икенче бер автор).

**СОА'ВТОРСКИЙ** *книж.*— автордаш ...-ы, уртак авторлык...-ы, автордашлык...-ы; *соавторский гонорар* — автордашлык гонорары.

**СОА'ВТОРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — автордашлык.

**СОАРЕ'НДА** *ж. мн.* нет, *офиц. право* — уртак аренда, бергәләп арендага алу.

**СОАРЕНДА'ТОР** *м. офиц.* — арендада катнашучы, уртакка арендага алучы.

**СОБА'КА** *ж.* — эт. ◇ **Вот где собака зарыта** *разг.* — менә аның сере кайда икән! Хикмәте менә кайда икән! имәндә (юкәдә) икән чикләвек! **Как собак нерезан(н)ых** *разг. фам.*— бик күп, чиктән тыш күп; ...-ка типсәң, эткә тия. **Собака собакой** *простореч. фам.* — эт кебек, этнең дә эте. **Собак вешать на** *кого-что* или **на шею** *кому-чему* — сүгү, тиргәү, бәла тагу. **Собаку съесть на чём** *разг. шутл.* — теше төшү, теше коелу (нинди дә бер эштә, фәндә зур тәҗрибә алу, осталыгы зур булу). **С собаками не сыщешь** *разг. шутл.* — эт белән дә эзләп таба алмассың, эзе дә юк, җилләр искән. **Устать, как собака** *простореч.* — эт булу, эт булып бетү, эт кебек ару. **Как кошка с собакой** — к. кошка.

**СОБАКОВЕ'Д** *м.* — этләр белгече.

**СОБАКОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — эт асраучылык белеме (этләрне үрчетү һәм алардан файдалану методлары турындагы белем).

**СОБАКОВО'Д** *м.* — эт асраучылык белгече, эт үрчетүче.

**СОБАКОВО'ДСТВО** *ср.* — 1. *только ед.* эт асраучылык (этләрне үрчетү һәм аларның токымын яхшырту); 2. эт асраучылык хуҗалыгы.

**СОБАКООБРА'ЗНЫЙ** *зоол. спец.* — этсыман, эткә охшаш; *собакообразные обезьяны* — этсыман маймыллар.

**СОБАЧА'ТА** *только мн. разг. фам.* — кечкенә этләр; эт балалары, көчекләр.

**СОБАЧЕ'Й** *м. устар.* — к. собачник 1.

**СОБА'ЧИЙ** — эт ...-ы; *собачий корм* — эт азыгы. ◇ **Собачья жизнь** *простореч.* — эт тормышы (авыр тормыш). **Собачье отродье** *простореч. вульг.* — эт токымы. **Собачий сын** *простореч. вульг.* — эттән туган, эт малай. **Собачий холод** *разг.* — зәмһәрир суыгы, катып үләрлек суык. **Собачья радость** *разг. фам.* — эткә шатлык, эт куанычы (начар колбаса турында әйтелә). **Собачья старость** *разг. фам. шутл.* — 30 яшь.

**СОБА'ЧИНА** *ж. мн.* нет, *обл.* — эт ите.

**СОБА'ЧИТЬСЯ** *несов. простореч. фам.* — этләшү, тиргәшү, әрләшү.

**СОБА'ЧКА** I *ж.* — 1. тияк (механизмнарда махсус җайланма); 2. *обл., спец.* чөй.

**СОБА'ЧКА** II *ж.* — кечкенә эт, мүчкәй.

**СОБА'ЧЛИВЫЙ** *простореч. фам.* — этләшүчән, тиргәшүчән, әрләшүчән.

**СОБА'ЧНИК** *м.*, **СОБА'ЧНИЦА** *ж. разг.* — 1. эт яратучы, эт сөюче; 2. этләр белән җәнлек аулаучы; 3. *устар.* этләр белән сату итүче, эт(ләр) сатучы.

**СОБЕСЕ'ДНИК** *м.*, **СОБЕСЕ'ДНИЦА** *ж.* — бергә сөйләшеп утыручы, әңгәмәдәш, утырдаш, гәптәш.

**СОБЕСЕ'ДОВАНИЕ** *ср. книж.* — (фәнни, политик һ. б. темага үткәрелгән) беседа, әңгәмә, сөйләшү.

**СОБИРА'ТЕЛЬ** *м.*, **СОБИРА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — җыючы, туплаучы; *собиратель книг* — китаплар җыючы.

**СОБИРА'ТЕЛЬНО** *нареч. книж.* — гомумән, тулаем, барысын бергә җыеп, аерымаерым тукталмыйча.

**СОБИРА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. *грам.* җыйма...; *собирательные имена существительные* — җыйма исемнәр; 2. *спец.* җыелмалы, җыела торган (аерым кисәкләрдән җыела торган); *собирательные кольца* — җыелмалы балдаклар (боҗралар).

**СОБИРА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. коллекционерлык, коллекция(ләр) җыючылык; 2. *экон.* җыючылык, яшәү өчен кирәк нәрсәләрне җыю (гөмбә, чәчәк, җиләкҗимеш җыю, балык тоту һ. б.).

**СОБИРА'ТЬ** *несов.* — к. собрать.

**СОБИРА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. собраться; 2. *страд.* җыелу, җыеп алыну, җыеп куелу; 3. *страд.* тупланү, туплап куелу; 4. *страд.* корылу; 5 *страд. порт.* бөрелү.

**СОБЛАГОВОЛИ'ТЬ** *сов. с инф. книж. устар., теперь ирон.* — рәхим итеп ...-у; *он соблаговолил прийти* — ул рәхим итеп килде; *соблаговолите ответить* — рәхим итеп җавап бирегезче.

**СОБЛАГОВОЛЯ'ТЬ** *несов. книж. устар., теперь ирон.* — к. соблаговолить.

**СОБЛА'ЗН** *м.* — 1. кызыгырлык нәрсә, кызыктыра торган нәрсә; *в магазинах много соблазнов для ребят* — кибетләрдә балаларны кызыктыра торган нәрсәләр бик күп; 2. *церк.* вәсвәсә, күңел аздыргыч, юлдан яздыргыч (нәрсә). ◇ **Ввести** *кого-н.* **в соблазн** — берәр кешенең күңелен аздыру, вәсвәсәләү.

**СОБЛАЗНИ'ТЕЛЬ** *м.*, **СОБЛАЗНИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж.* — 1. кызыктыручы, күңел аздыручы; 2. кызыктырып алдаучы, аздыручы.

**СОБЛАЗНИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — кызыктырырлык булу, кызыгырлык булу.

**СОБЛАЗНИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. кызыгырлык, кызыктырырлык; *соблазнительное предложение* — кызыктырырлык тәкъдим; 2. күңел аздыргыч, күңел аздыра торган, вәсвәсәле.

**СОБЛАЗНИ'ТЬ** *сов.* — 1. кызыктыру; *соблазнить перспективами летнего отдыха* — җәйге ял перспективалары белән кызыктыру; 2. *устар. неодобр.* алдау, аздыру.

**СОБЛАЗНИ'ТЬСЯ** *сов.* — кызыгу, күз кызу, күңел төшү.

**СОБЛАЗНЯ'ТЬ** *несов.* — к. соблазнить.

**СОБЛАЗНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. соблазниться; 2. *страд.* кызыктырылу; 3. *страд.* алдану, аздырылу, вәсвәсәләнү.

**СОБЛЮДА'ТЬ** *несов.* — 1. (дөрес) үтәү, җиренә җиткереп үтәү; 2. саклау, бозмау, ригая итү; *соблюдать дисциплину* — тәртип саклау.

**СОБЛЮДА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. (дөрес) үтәлү, җиренә җиткереп үтәлү; 2. саклану, бозылмау, ригая ителү.

**СОБЛЮСТИ'** *сов. книж.* — к. соблюдать.

**СОБОЛЕВО'Д** *м. спец.* — кеш асраучылык белгече, кеш үрчетүче.

**СОБОЛЕВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *спец.* — кеш асраучылык.

**СОБОЛЕВО'ДЧЕСКИЙ** *спец.* — кеш асрау(чылык) ...-ы; *соболеводческое хозяйство* — кеш асрау хуҗалыгы.

**СОБОЛЕ'ЗНОВАТЬ** *несов. книж.* — кайгысын уртаклашу.

**СОБОЛЁНОК** *м. (мн.* соболя́та*)* — кеш баласы.

**СОБО'ЛИЙ** — 1. кеш ...-ы; *соболий мех* — кеш мехы; 2. кеш (мехыннан тегелгән); *соболий воротник* — кеш яка (кеш мехыннан тегелгән).

**СОБОЛИ'НЫЙ** *устар.* — к. соболий. ◇ **Соболиные брови** *перен нар.-поэт.* — куе кара каш.

**СО'БОЛЬ** *м.* — 1. кеш; 2. кеш мехы; 3. *только мн. устар.* кеш мехыннан ясалган муенса.

**СОБОЛЮ'ШКА** *ж. спец.* — ана кеш.

**СОБОЛЯ'ТНИК** *м. спец.* — 1. кеш аулаучы; 2. кеш питомнигында эшләүче.

**СОБО'Р** *м.* — собор (1. борынгыда: җыелыш, съезд; 2. шәһәрнең яки монастырьның иң зур чиркәве).

**СОБО'РНЕ** и **СОБО'РНО** *нареч. церк.* — бөтен собор белән, барысы бергә.

**СОБО'РНЫЙ** — 1. собор ...-ы; *соборный купол* — собор гөмбәзе; 2. *устар.* гомуми; бергәләп ...-ган; *соборное торжество* — гомуми тантана.

**СОБОРЯ'НИН** *м. церк.* — соборда хезмәт итүче рухани.

**СОБРА'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. канц.* (*действие*) җыю, җыеп алу; *по собрании всех сведений приступить к своду их* — барлык мәгълүматларны җыеп алганнан соң (җыеп алгач), аларны берләштерүгә керешергә; 2. җыелыш; *собрание избирателей* — сайлаучылар җыелышы; 3. җыелыш, җыелышта катнашучылар; *собрание приняло резолюцию* — җыелыш резолюция кабул итте; 4. собрание; *учредительное собрание* — учредительное собрание; 5. җыентык; *собрание сочинений Ленина* — Ленин әсәрләре җыентыгы; 6 җыелма, туплама, коллекция; *собрание редких книг* — сирәк очрый торган китаплар җыелмасы (коллекциясе).

**СО'БРАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — (бергә) тупланганлык, (бергә) тупланган булу; *в бою требуется собранность всех сил человека* — сугышта кешенең барлык көчләре (бергә) тупланган булуы таләп ителә.

**СО'БРАННЫЙ** — 1. җыелган, тупланган,

жыеп алынган, туплап куелган; 2. һәрвакыт әзер, һәрнәрсәгә дә әзер, зиһене таркалмаган.

**СОБРА'Т** *м. книж. ритор.* — хезмәттәш, иптәш.

**СОБРА'ТЬ** *сов.* — 1. жыю, жыеп алу; ***собрать участников похода*** — походта катнашучыларны жыю; 2. жыю, жыеп алу, жыеп кую, туплау, туплап кую; ***собрать налоги*** — салымнар жыю; ***собрать огурцы с гряд*** — түтәлләрдән кыярларны жыеп алу; ***собрать вещи в угол*** — әйберләрне почмакка жыеп кую (туплап кую); 3. *разг.* әзерләү, жыю; ***собрать обед*** — төшке ашны әзерләү (табын жыю); 4. жыйнау, әзерләү; 5. кору, жыю; ***собрать радиоприёмник*** — радиоалгычны кору; 6. *порт.* бөрү; ***собрать платье в талии*** — күлмәкнең биле бөрү. ◇ **Собрать мысли** — зиһенне туплау. **Собрать всё тело** — (нинди дә булса хәрәкәт ясарга) әзер хәлгә килү. **Собрать лошадь** *спорт. воен.* — (атны хәрәкәт ясарга) әзер хәлгә китерү.

**СОБРА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. жыелу, туплану; ***собралось много знакомых*** — бик күп танышлар жыелды; ***собралось много книг*** — бик күп китап жыелган; 2. *обл.* киенү; ***собралась потеплее*** — жылырак киенде; 3. жыену, әзерләнү; ***собраться в гости*** — кунакка барырга жыену; 4. жыю, туплау; ***собраться с силами*** — көчләрне жыю. ◇ **Собраться с духом** *разг.* — 1. тын алу, сулыш алу, ял итү (йөгерүдән соң); 2. батырчылык итү. **Собраться в комок** — йомарлану, бөгәрләнү.

**СО'БСТВЕННИК** *м.*, **СО'БСТВЕННИЦА** *ж.* — 1. биләүче, хосусый милекче, хосусый милек иясе; ***дворяне были крупными земельными собственниками*** — двояннар эре жир биләүчеләр булганнар; 2. *перен.* комсыз, ач күзле, үз ягын гына караучы.

**СО'БСТВЕННИЧЕСКИЙ** *книж. неодобр.* — хосусый милекче ...-ы; хосусый милек ияләренә хас (булган).

**СО'БСТВЕННО** — 1. *вводн. сл.* чынында, дөресен (әйткәндә); ***собственно говоря, он прав*** — дөресен әйткәндә, ул хаклы; 2. *частица* үзе; ***волжскую систему составляют собственно Волга и её притоки*** — Идел системасына Идел елгасы үзе һәм аның кушылдыклары керә.

**СОБСТВЕННОРУ'ЧНО** *нареч.* — үз кулы белән.

**СОБСТВЕННОРУ'ЧНЫЙ** *книж. канц.* — үз кулы белән куелган (язылган).

**СО'БСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — милек. ◇ **Приобрести в собственность** (*что-либо*) — (берәр нәрсәне) үзенә алу.

**СО'БСТВЕННЫЙ** — 1. үз; ***собственный дом*** — үз йорты(м, ң); ***в собственные руки*** — үз кулына (ңа, ма); ***по собственному желанию*** — үз теләге(м, ң) белән; 2. чын; ***в собственном смысле слова*** — сүзнең чын мәгънәсендә. ◇ **Чувство собственного достоинства** — үз кадерен үзе белү. **Имя собственное** *грам.* — ялгызлык исем.

**СОБУТЫ'ЛЬНИК** *м. разг.* — шешәдәш, бергә эчүче, бергә эчеп йөрүче.

**СОБЫ'ТИЕ** *ср.* — вакыйга; хәл.

**СОБЫТИ'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. лит.* — вакыйгаларга (фактларга) бай булу.

**СОБЫТИ'ЙНЫЙ** *книж. лит.* — вакыйгаларга бай, фактларга бай.

**СОВА'** *ж.* — ябалак, мәче башлы ябалак.

**СОВА'ТЬ** *несов.* — 1. тыгу; ***не суй руки в карманы*** — кулларыңны кесәләреңә тыкма; 2. тоттыру; ***совать книги в руки*** — кулларына китаплар тоттыру; 3. *разг.* төртү; ***совать взятку*** — взятка төртү. ◇ **Совать рыло** или **лапу** *разг. фам.* — борын тыгу, (кеше эшенә) тыгылу; тыкшыну.

**СОВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *обл.* әрле-бирле йөрү, ыгы-зыгы килеп йөрү; 2. *неодобр.* тыгылу, тыкшыну, кысылу; ***соваться в чужие дела*** — кеше эшенә тыгылу; ***во всё суётся*** — һәр эшкә тыгыла (тыгылмаган жире юк). ◇ **Соваться вперёд** — алга чыгу. **Соваться с носом** — к. нос.

**СОВЁНОК** *м. (мн.* совята*)* — ябалак баласы, мәче башлы ябалак баласы.

**СОВЕРША'ТЬ** *несов. книж.* — к. совершить.

**СОВЕРША'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. совершиться; 2. *страд.* ясалу, эшләнү.

**СОВЕРШЕ'ННО** *нареч.* — 1. бөтенләй, тулысынча, тәмам; ***совершенно оглох*** — бөтенләй чукракланган; 2. *с отриц.* „не" һич, һич тә, бер дә; ***совершенно не соответствует*** — һич тә туры килми; ***совершенно не надо*** — һич тә кирәге юк, бер дә кирәге юк. ◇ **Совершенно слепой** — дөм-сукыр. **Совершенно верно** — бик дөрес, дөп-дөрес. **Совершенно необходимо** — бик кирәк. **Совершенно раздетый** — шыр ялангач, яп-ялангач.

**СОВЕРШЕННОЛЕ'ТИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. право* — яше житү, буйга житү, балигълык, балигъ булу.

**СОВЕРШЕННОЛЕ'ТНИЙ** *книж. право* — яше житкән, буйга житкән, балигъ булган.

**СОВЕРШЕ'ННЫЙ** I — 1. *книж.* камилләштерелгән, камилләшкән; ***применение наиболее совершенных средств обороны*** — югары дәрәҗәдә камилләштерелгән оборона чараларын куллану; 2. тулы, булуы житкән; ***совершенная красота*** — тулы матурлык; 3. тулысынча..., бөтенләй...; ***совершенное разорение*** — бөтенләй бөлү; 4. *разг.* ашып узган, шыр; ***совершенный идиот*** — шыр тиле. ◇ **Человек в совершенных летах** или **годах** — яше житкән кеше, балигъ булган кеше. **Совершенная правда** — чын хакыйкать, һичшиксез дөрес. **Совершенная невежда** — чеп-чи надан.

**СОВЕРШЕ'ННЫЙ** II: **совершенный вид** *грам.* — тәмамланган күренеш (грамматикада: фигыль белдерә торган эшнең вакыт ягыннан чикләнгәнлеген, мәсәлән, эшнең тәмамлануын, нәтиҗәсен, башлануын яки аның аерым бер моментын белдерә торган категория).

**СОВЕРШЕ'НСТВО** *ср.* — 1. камиллек; ***верх совершенства*** — камиллекнең иң югары дәрәҗәсе; ***стремиться к совершенству*** — камиллеккә омтылу; 2. идеал. ◇ **Вла-**

деть в совершенстве французским языком — француз телен бик яхшы белү.

**СОВЕРШЕ'НСТВОВАТЬ** *несов.*— камилләштерү.

**СОВЕРШЕ'НСТВОВАТЬСЯ** — 1. *сов. устар.* и *несов.* камилләшү; 2. *несов. страд.* камилләштерелү.

**СОВЕРШИ'ТЕЛЬ** *м. книж. ритор.*— 1. кылучы, ясаучы, эшләүче; *совершитель преступления* — җинаять эшләүче; 2. күрсәтүче; *совершитель подвига* — батырлык (каһарманлык) күрсәтүче.

**СОВЕРШИ'ТЬ** *сов.*— 1. кылу, ясау, эшләү; *совершить ошибку* — хата ясау; *совершить преступление* — җинаять эшләү; 2. күрсәтү; *совершить подвиг* — батырлык (каһарманлык) күрсәтү; 3. *офиц.* ясау, төзү; *совершить сделку* — договор төзү; 4. *офиц. поэт.* башкару, үтәү (берәр төрле йоланы). ◇ **Совершить кражу** — урлау. **Совершить омовение** *рел.*— тәһарәт алу, госел коену.

**СОВЕРШИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— 1. *высок.* булу, килеп чыгу; *совершилось нечто неожиданное* — көтелмәгән бер хәл булды; 2. *офиц., поэт.* башкарылу, үтәлү; *омовение совершилось* — тәһарәт алу (йоласы) үтәлде.

**СО'ВЕСТИТЬ** *несов. устар.*— оялту, инсафка китерергә тырышу, гарьләндерү.

**СО'ВЕСТИТЬСЯ** *несов.*— вөждан бармау, вөжданы күтәрмәү; оялу, гарьләнү.

**СО'ВЕСТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — вөжданлылык, инсафлылык, ояла белүчәнлек.

**СО'ВЕСТЛИВЫЙ** — вөжданлы, инсафлы, ояла белүчән.

**СО'ВЕСТНО** *в знач. сказ. с инф.* или *с союзом „что" разг.*— оят, уңайсыз; оялу, уңайсызлану; *как вам не совестно!* — оят түгелмени сезгә! *совестно просить денег* — акча сорарга оялам.

**СО'ВЕСТНЫЙ** *устар.*— к. совестливый.

**СО'ВЕСТЬ** *ж. мн.* нет — вөждан, оят, инсаф. ◇ **Ни стыда, ни совести нет** — вөжданы да, ояты да юк; бер дә ояты юк. **Без зазрения совести** — к. зазрение. **Для очистки совести** — күңелне тынычландырыр өчен. **На совесть** *разг.*— намус белән, күңел биреп; тырышып, яхшы; *поработали на совесть* — күңел биреп эшләдек, намус белән эшләдек; *сделать что-н. на совесть* — берәр нәрсәне тырышып (яхшы) эшләү. **Не за страх, а за совесть** — күңел биреп, чын күңелдән, тырышып. **По совести или говоря** (сказать) **по совести** *ввод. сл. разг.*— чын күңелдән әйткәндә (ачыктан-ачык кына әйткәндә, дөресен генә әйткәндә). **По чистой совести** *разг.*— чын күңелдән (әйткәндә), ачыктан-ачык (әйткәндә). **Со спокойной совестью** — үзеңең хаклыгына ышанып, үзеңең хаклы булуына ышанып, саф вөждан белән, бик тыныч кына; *со спокойной совестью могу сказать* — саф вөждан белән әйтә алам. **Поступить по совести** — вөжданы кушканча эш итү. **Это у меня лежит на совести** — 1. гаеп миндә; 2. моның өчен җаваплылык минем өстемә төшә. **Свобода совести** *полит.*— вөждан иреге; *в целях обеспечения за гражданами свободы совести церковь в СССР отделена от государства и школа от церкви* — гражданнарның вөждан иреген тәэмин итү максаты белән СССРда чиркәү дәүләттән һәм мәктәп чиркәүдән аерылган.

**СОВЕ'Т** I *м.*— 1. киңәш; *дать хороший совет* — яхшы киңәш бирү; 2. совет; *учёный совет института* — институтның гыйльми советы. ◇ **Жить в совете** *устар.*— дус яшәү, тату яшәү. **Совет да любовь** *устар.*— тату яшәгез, бәхетле (тату) тормыш телим.

**СОВЕ'Т** II *м.*— совет; *власть Советов* — Советлар власте; *сельский совет* — авыл советы; *страна Советов* — Советлар иле.

**СОВЕ'ТНИК** *м.*— 1. киңәшче, киңәш бирүче; *мой постоянный советник* — минем даими киңәшчем; 2. советник; *советник посольства* — илчелек советнигы; 3. *дорев. офиц.* советник.

**СОВЕ'ТНИЦА** *ж.*— 1. к. советник 1; 2. *дореволь. разг.* советник хатыны.

**СОВЕ'ТОВАТЬ** *несов.*— киңәш бирү; киңәш итү; мәслихәт күрү.

**СОВЕ'ТОВАТЬСЯ** *несов.*— 1. киңәш сорау, киңәшү; *советоваться со старшим товарищем* — өлкән иптәшеңнән киңәш сорау; 2. киңәшү, киңәшләшү; *советоваться с друзьями* — дуслар белән киңәшләшү.

**СОВЕ'ТСКИЙ** — совет...-ы, советлар...-ы; *советская власть* — совет власте; *Советский Союз* — Советлар Союзы.

**СОВЕ'ТЧИК** *м.*, **СОВЕ'ТЧИЦА** *ж. разг.*— киңәшче, киңәш бирүче, акыл бирүче.

**СОВЕ'ТЬ** *несов. разг. фам.*— мәлҗерәү, әреп төшү.

**СОВЕЩА'НИЕ** *ср.*— 1. (*действие*) к. совещаться; 2. киңәшмә; *устроить совещание* — киңәшмә ясау; *совещание приняло резолюцию* — киңәшмә резолюция кабул итте.

**СОВЕЩА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. офиц.*— киңәш бирү...-ы; *совещательный орган* — киңәш бирү органы.

**СОВЕЩА'ТЬСЯ** *несов.*— киңәшү, киңәшләшү, фикер алышу.

**СОВИ'К** *м. обл.*— совик (төньяк халыкларында — йоны белән тышкы якка тегелгән башлыклы кием).

**СОВИНО'ВНОСТЬ** *м. мн.* нет, *право* — гаепташлек, җинаятьташлек, бергә җинаять эшләгәнлек.

**СОВИНО'ВНЫЙ** *право* — гаепташ, җинаятьташ, бергә җинаять эшләгән, җинаять эшләүдә катнашкан.

**СОВИ'НЫЙ** — ябалак...-ы, мәче башлы ябалак ...-ы; *совиное гнездо* — мәче башлы ябалак оясы.

**СО'ВКА** I *ж. мн.* нет, *обл.*— к. совать.

**СО'ВКА** II *ж.*— 1. *обл.* к. сова; 2. *зоол.* ябалакбаш, ябалакчык (төнге күбәләк; бу күбәләкнең корты авыл хуҗалыгы культураларына зур зарар китерә); *капустная совка* — кәбестә ябалакчыгы (кәбестә күбәләге).

**СО'ВКИЙ** *обл.*— 1. *неодобр.* тыкшыну-

чан, (һәрбер эшкә) кысылучан, тыгылучан; **2.** *спец. (о лошади)* елдам, елгыр.

**СО'ВКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *обл. спец.*— елдамлык, елгырлык.

**СОВЛАДА'ТЬ** *сов. разг.*— **1.** җиңү, тыю; тотып калу; *совладать с гневом* — ачуыны тотып калу (ачуны басып калу); **2.** кулга алу; *совладать с собой* — үзеңне кулга алу.

**СОВЛАДЕ'ЛЕЦ** *м.*, **СОВЛАДЕ'ЛИЦА** *ж. офиц.*— милектәш, уртак биләүче, бергә биләүче.

**СОВЛАДЕ'ТЬ I** *сов. обл.*— к. совладать.

**СОВЛАДЕ'ТЬ II** *несов. офиц. устар.*— уртак биләү, бергә биләү.

**СОВЛАДЫ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. ритор. устар.*— бергә хакимлек итү, уртак хакимлек итү.

**СОВЛЕКА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. совлечь.

**СОВЛЕКА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.*— **1.** к. совлечься; **2.** *страд.* салдырылу; **3.** *страд.* ачылу, төшерелү.

**СОВЛЕ'ЧЬ** *сов. книж. устар.*— **1.** салдыру, салдырып алу; *совлечь одежду* — киемен салдыру; **2.** тартып төшерү; *совлечь покровы* — япмаларны тартып төшерү. ◇ **Совлечь** *с кого-нибудь* **маску** *перен.*— йөзен ачу, фаш итү, битлеген салдыру.

**СОВЛЕ'ЧЬСЯ** *сов. книж. устар.*— төшү, тартып төшерелү; *покровы совлеклись* — япмалар төште.

**СОВМЕСТИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— бергә сыя алу, бергә сыю; туры килү, каршы булмау.

**СОВМЕСТИ'МЫЙ** *книж.*— бергә сыя торган, бергә сыя алырлык, бергә сыйдыруы (кушуы) мөмкин булган; туры килә торган, каршы булмаган; *это вполне совместимо с моими убеждениями* — бу минем фикерләремә тулысынча туры килә (каршы түгел).

**СОВМЕСТИ'ТЕЛЬ** *м.*, **СОВМЕСТИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. офиц.*— ике (яки берничә) эшне берьюлы башкаручы, ике (яки берничә) урында эшләүче.

**СОВМЕСТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.*— к. совместимый.

**СОВМЕСТИ'ТЕЛЬСКИЙ** — (икенче бер эш белән) бергә үтәлә торган, (икенче бер эш белән) бергә алып барыла торган.

**СОВМЕСТИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *офиц.*— ике (яки берничә) урында берьюлы эшләү, ике (яки берничә) эшне берьюлы башкару.

**СОВМЕСТИ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов.*— ике (яки берничә) урында берьюлы эшләү; ике (яки берничә) эшне берьюлы башкару, ике (яки берничә) эшне бергә алып бару, ике (яки берничә) вазифаны берьюлы үтәү.

**СОВМЕСТИ'ТЬ** *сов.*— **1.** бергә сыйдыру, бергә кушу; берләштерү; *совместить разнородные понятия* — төрле төшенчәләрне берләштерү; **2.** берләштерү, бер үк вакытта булу; *Скрябин совместил в себе замечательного композитора и пианиста* — Скрябин бер үк вакытта бик яхшы композитор да, пианист та булган.

**СОВМЕСТИ'ТЬСЯ** *сов.*— бер үк вакытта булу, берләшү, кушылу; *в нём совместились большие теоретические познания и практический опыт* — анарда бер үк вакытта зур теоретик белем дә, практик тәҗрибә дә бар.

**СОВМЕ'СТНИК** *м.*, **СОВМЕ'СТНИЦА** *ж. книж. устар.*— конкурент, ярышучы.

**СОВМЕ'СТНО** *нареч.*— бергә, бергәләп, бергәләшеп, бергәлектә.

**СОВМЕ'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — бергә булу, бергәлек.

**СОВМЕ'СТНЫЙ** — **1.** бергә..., бергәләп...; *совместная работа* — бергә эшләү; **2.** берләштерелгән, бергә үткәрелгән; *совместное заседание* — берләштерелгән утырыш; **3.** *устар.* к. совместимый.

**СОВМЕЩА'ТЬ** *несов.*— **1.** к. совместить; **2.** *офиц.* ике (яки берничә) вазифаны берьюлы үтәү (бергә үтәү, бер үк вакытта үтәү), ике (яки берничә) эшне берьюлы башкару, ике (яки берничә) урында берьюлы эшләү; *совмещать должность машинистки и секретаря* — машинистка һәм секретарь вазифаларын берьюлы үтәү; *он совмещает в двух учреждениях* — ул берьюлы ике учреждениедә эшли.

**СОВМЕЩА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. совместиться; **2.** *страд.* бергә сыйдырылу, бергә кушылу, берләштерелү.

**СОВО'К** *м.*— соскы, соскыч.

**СОВОКУПИ'ТЬ** *сов. книж. устар.*— берләштерү, кушу, бергә сыйдыру.

**СОВОКУПИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— **1.** бергә җыелу, бергә туплану, кушылу, берләшү; *здесь совокупилось много затруднений* — монда бик күп кыенлыклар бергә җыелган; **2.** *устар. (войти в соглашение)* килешү; **3.** якынлык кылу.

**СОВОКУПЛЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. совокупить.

**СОВОКУПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.*— **1.** к. совокупиться; **2.** *страд. устар.* берләштерелү, кушылу, бергә сыйдырылу.

**СОВОКУ'ПНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— барлыгы бергә, ... җыелмасы.

**СОВОКУ'ПНЫЙ** *книж.*— **1.** бердәм..., берләштерелгән; *совокупные усилия* — бердәм көч куюлар; **2.** бергәләп...; бергәләп ...-ган; *совокупные действия* — бергәләп хәрәкәт итү (эш күрү).

**СОВПАДА'ТЬ** *несов.*— к. совпасть.

**СОВПА'СТЬ** *сов.*— **1.** бер үк вакытка туры килү, бер вакытта булу; *это событие совпало с его приездом* — бу вакыйга ул килгән вакытка туры килде; **2.** туры килү; *мнения их совпали* — аларның фикерләре туры килде; **3.** *мат.* (үзара) тәңгәл килү; *многоугольники совпали* — күппочмаклар үзара тәңгәл килделәр.

**СОВРАТИ'ТЕЛЬ** *м.*, **СОВРАТИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж. устар.*— юлдан яздыручы, аздыручы, бозык юлга кертүче, бозык юлга бастыручы, яман юлга бастыручы.

**СОВРАТИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.*— юлдан яздыра торган, аздыргыч, аздыра торган, бозык юлга бастыра торган.

**СОВРАТИ'ТЬ** *сов. книж.*— юлдан язды-

ру, аздыру, бозык юлга кертү, бозык юлга бастыру, яман юлга бастыру.

**СОВРАТИ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— юлдан язу, азу, бозык юлга керү, бозык юлга басу.

**СОВРА'ТЬ** *сов. разг.*— ялганлау, ялган сөйләү, ялган сүз ычкындыру, ялган сүз әйтү.

**СОВРАЩА'ТЬ** *несов. книж.*— к. совратить.

**СОВРАЩА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— **1.** к. совратиться; **2.** *страд.* юлдан яздырылу, аздырылу, бозык юлга кертелү, бозык юлга бастырылу, яман юлга кертелү.

**СОВРЕМЕ'ННИК** *м.*, **СОВРЕМЕ'ННИЦА** *ж.*— замандаш, бер чор кешесе.

**СОВРЕМЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — хәзерге заман, хәзерге чор, хәзерге көн.

**СОВРЕМЕ'ННЫЙ — 1.** замандаш ..., замандаш булган, бер чорда яшәгән; *современные Пушкину поэты* — Пушкин белән бер чорда яшәгән шагыйрьләр; **2.** ...чорындагы, ...яшәгән чорда булган; *современная Гоголю критика* — Гоголь яшәгән чорда булган тәнкыйть; **3.** хәзерге заман..., хәзерге чор..., хәзерге көн..., хәзерге; *современная жизнь* — хәзерге тормыш; *современная литература* — хәзерге заман әдәбияты, хәзерге әдәбият; *современная техника* — хәзерге заман техникасы.

**СОВСЕ'М** *нареч* — һич тә, бер дә, бөтенләй; *я этого совсем не ожидал* — мин моны һич тә көтмәгән идем; *он меня совсем не знает* — ул мине бөтенләй белми. ◇ **Совсем новый** — әр-яңа. **Совсем слепой** — дөм-сукыр. **Совсем голый** — ял-ялангач, шыр-ялангач.

**СОВХО'З** *м.*— совхоз.

**СОВХО'ЗНЫЙ** — совхоз ...-ы, совхозлар ...-ы; *совхозные поля* — совхоз кырлары.

**СОГБЕ'ННЫЙ** *книж. устар.*— бөкрәйгән; *согбенный старец* — бөкрәйгән карт.

**СОГЛА'СИЕ** *ср.*— **1.** ризалык; *дать согласие на что-нибудь* — берәр нәрсәгә ризалык бирү; **2.** *только ед.* килешү; *действовать по общему согласию* — үзара килешеп эш итү; **3.** *только ед.* килешү, (фикергә) кушылу; *выразить своё согласие с мнением оратора* — ораторның фикеренә кушылуыңны белдерү; **4.** *только ед.* дуслык, татулык, бердәмлек; *в их семье царит полное согласие* — аларның семьясында тулы татулык хөкем сөрә; **5.** *только ед. устар.* үзара ярашу, үзара ярашканлык, гармониялелек, ятышлык, килешлелек; *согласие всех частей здания* — бинаның барлык өлешләренең үзара ярашканлыгы; **6.** *только ед. устар.* аһәң, аһәңлелек; *в оркестре нет согласия* — оркестрда аһәңлелек юк; **7.** *только ед. перен. устар.* (*о красках*) үзара ярашканлык; **8.** *религ.* согласие (староверларда — аерым бер мәзһәп, агым). ◇ **В согласии с** *чем* *книж. канц.* — ... буенча, ярашлы рәвештә.

**СОГЛАСИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. офиц.*— килештерү ...-ы; *согласительная комиссия* — килештерү комиссиясе.

**СОГЛАСИ'ТЬ** *сов. книж.*— **1.** үзара килештерү, үзара татулаштыру; *согласить противоречия* — каршылыкларны үзара килештерү; **2.** *устар.* (*уговорить на что-н.*) күндерү.

**СОГЛАСИ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** риза булу, күнү; *согласиться прийти* — килергә риза булу; **2.** килешү, (фикергә) кушылу; *согласиться с мнением докладчика* — докладчының фикеренә кушылу; **3.** сөйләшү, килешү, булу; *мы согласились ехать вместе* — без бергә барырга сөйләштек, без бергә барырга булдык. ◇ **Согласись, что ты был неправ** *разг.*— әйт инде, син хаксыз идең бит.

**СОГЛА'СНО** I *нареч.*— **1.** тату, дус; *жить согласно* — тату яшәү; **2.** (*единодушно*) бердәм рәвештә.

**СОГЛА'СНО** II *предлог с дат. п.* или *с предлогом „с“* — буенча, ... ярашлы рәвештә, ...-га таянып, ...-га туры китереп; *поступать согласно с законом* или *согласно закону* — законга таянып эш итү, закон буенча эш итү.

**СОГЛА'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— **1.** татулык, дуслык; **2.** *устар.* аһәңлелек. ◇ **В согласность с** *чем* *устар.*— буенча, ... ярашлы рәвештә, ...-га таянып, ...-га туры китереп.

**СОГЛА'СНЫЙ** I — **1.** риза булган, күнгән; *в знач. сказ.* риза; *согласен на все условия* — барлык шартларга да риза; **2.** килешкән, (фикергә) кушылган; *в знач. сказ.* килешә(м, сең), (фикергә) кушыла(м, сың); *я с тобой не согласен* — мин синең белән килешмим; **3.** *книж.* туры килә торган; *в знач. сказ.* туры килә; *копия согласна с подлинником* — күчермә төп нөсхәсенә туры килә; **4.** тату, дус; *согласная семья* — тату семья; **5.** *устар.* аһәнле.

**СОГЛА'СНЫЙ** II *лингв.*— **1.** тартык; *согласные звуки* — тартык авазлар; **2.** *в знач. сущ.* тартык аваз.

**СОГЛАСОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — **1.** (*действие*) к. согласовать; **2.** *грам.* ярашу; яраштыру.

**СОГЛАСО'ВАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — бердәмлек, берләшкәнлек, берләштерелгәнлек, үзара килешеп эшләү.

**СОГЛАСО'ВАННЫЙ** — **1.** туры китерелгән; килештерелгән; **2.** хәл ителгән, килешелгән, сөйләшенгән; **3.** берләшкән, берләштерелгән, үзара килешеп эшләнгән; *согласованные действия* — берләштерелгән хәрәкәтләр; **4.** *грам.* ярашкан, яраштырылган.

**СОГЛАСОВА'ТЬ** *сов.*— **1.** килештерү, яраштыру, туры китерү; *согласовать интересы разных сторон* — төрле якның интересларын килештерү; **2.** хәл итү, килешү, сөйләшү; *надо согласовать вопрос с правлением* — мәсьәләне идарә белән хәл итәргә кирәк; **3.** *грам.* яраштыру.

**СОГЛАСОВА'ТЬСЯ** — **1.** *несов.* и *реже сов. устар.* туры китереп эшләү, исәпкә алып эшләү, игътибарга алып эшләү, истә тотып эшләү, ...-дан чыгып эшләү, ...-дан чыгып эш итү; *согласоваться с принятыми на себя обязательствами* — өстенә алган йөкләмәләрне истә тотып эшләү; **2.** *несов.*

*и реже сов. перен.* туры килү; *это распоряжение не согласуется с установленным ран·е порядком* — бу боерык элек урнаштырылган тәртипкә туры килми; **3.** *несов. грам.* ярашу.

**СОГЛАСО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. согласовать.

**СОГЛАСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— **1.** килештерелү, туры китерелү; **2.** хәл ителү, килешелү; **3.** *грам.* ярaштырылу.

**СОГЛАША'ТЕЛЬ** *м. полит. презрит.*— килешүчән, соглашатель (эшчеләр оешмаларында буржуазия белән килешүчәнлек политикасын, эшчеләр сыйныфының интересларына хыянәт итү политикасын алып баручы оппортунист).

**СОГЛАША'ТЕЛЬСКИЙ** *полит. презрит.*— **1.** соглашатель...; *соглашательские партии* — соглашатель партияләр; **2.** соглашательлек ...-ы, килешүчәнлек ...-ы; *соглашательская политика меньшевиков* — меньшевикларның соглашательлек политикасы.

**СОГЛАША'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *презрит.* — соглашательлек, соглашательлек политикасы, килешүчәнлек, килешүчәнлек политикасы.

**СОГЛАША'ТЬ** *несов. книж.*— к. согласить.

**СОГЛАША'ТЬСЯ** *несов.*— к. согласиться.

**СОГЛАШЕ'НИЕ** *ср.*— **1.** *только ед. книж. (действие)* к. согласить 1; **2.** *только ед. книж. (действие)* к. согласиться 2; **3.** *только ед.* килешү; бер сүзгә килү, бер фикергә килү; *достичь соглашения* — килешүгә ирешү; **4.** килешү, договор; *торговое соглашение* — сәүдә договоры.

**СОГЛЯДА'ТАЙ** *м. книж. устар.*— шымчы, шпион.

**СОГНА'ТЬ** *сов.*— **1.** куу, куып төшерү, куып җибәрү; *согнать с места* — урыныннан куу; **2.** *спец.* агызу; *согнать лес* — агач агызу; **3.** бетерү; *согнать веснушки с лица* — биттәге сипкелләрне бетерү; **4.** куып китереп җыю, куып бер җиргә җыю; туплау; *согнать скот* — малны куып бер җиргә җыю. ◇ **Согнать со света** — к. свет II.

**СОГНУ'ТЬ** *сов.*— **1.** бөгү, кәкрәйтү, бөгеп кую; *согнуть проволоку* — тимер чыбыкны бөгү; **2.** бөкрәйтү; *годы согнули его* — аны еллар бөкрәйткән; **3.** *перен. разг.* какшату; *лишения и неудачи согнули его* — мохтаҗлыклар һәм уңышсызлыклар аны какшатты. ◇ **Согнуть в бараний рог** — к. бараний. **Согнуть в дугу** — к. дуга. **Согнуть в три погибели** — **1.** бик каты бөгү; **2.** *перен.* бик каты кысу, җәфалау.

**СОГНУ'ТЬСЯ** *сов.*— **1.** бөгелү; *проволока согнулась* — тимер чыбык бөгелде; **2.** бөкрәю.

**СОГРАЖДАНИ'Н** *м.*, **СОГРАЖДА'НКА** *ж. книж.*— ватандаш, илдәш гражданин; җәмгыятьтәш.

**СОГРЕВА'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — җылыта торган; *согревательный компресс* — җылыта торган компресс.

**СОГРЕВА'ТЬ** *несов.*— к. согреть.

**СОГРЕВА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. согреться; **2.** *страд.* җылытылу, җылытып куелу.

**СОГРЕ'ТЬ** *сов.*— **1.** җылыту, җылытып кую; *согреть котёл воды* — бер казан су җылыту; **2.** *перен. разг.* күңелен җылыту, күңелен күтәрү, юату, күңеленә җылы кертү.

**СОГРЕ'ТЬСЯ** *сов.*— җылыну; *руки согрелись* — кулларым җылынды.

**СОГРЕША'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. грешить.

**СОГРЕШЕ'НИЕ** *ср. книж. устар.*— **1.** *(действие)* к. грешить 1; **2.** гөнаһ, язык, ярамаган эш.

**СОГРЕШИ'ТЬ** *сов.*— к. грешить.

**СО'ДА** *ж. мн.* нет — сода.

**СОДВИГА'ТЬ** *несов. устар. обл.*— к сдвигать.

**СОДВИГА'ТЬСЯ** *несов. устар. обл.*— к. сдвигаться.

**СОДВИ'НУТЬ** *сов. устар. обл.*— к. сдвинуть.

**СОДВИ'НУТЬСЯ** *сов. устар. обл.*— к. сдвинуться.

**СОДЕ'ЙСТВИЕ** *ср.*— ярдәм, булышлык.

**СОДЕ'ЙСТВОВАТЕЛЬ** *м. книж. устар.*— ярдәмче, ярдәм күрсәтүче, булышчы, булышучы.

**СОДЕ'ЙСТВОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— ярдәм итү, ярдәм күрсәтү, булышу, булышлык итү, булышлык күрсәтү.

**СОДЕРЖА'НИЕ** *ср. мн.* нет — **1.** *(действие)* к. содержать 1, 2; **2.** эчтәлек; *содержание книги* — китапның эчтәлеге; *содержание доклада* — докладның эчтәлеге; **3.** *спец.* состав; *содержание сплава* — эретмәнең составы; **4.** микъдар; *определить содержание сахара в свекле* — чөгендердәге шикәрнең микъдарын билгеләү; **5.** *офиц.* хезмәт хакы; *получить месячное содержание* — айлык хезмәт хакын алу. ◇ **Руда с богатым содержанием** — металлга бай руда. **Жить или быть на содержании** *у кого-н. устар.*— (берәр кешедә) тәрбияләнеп тору; (берәр кешенең) хисабына яшәү, (берәр кешенең) җилкәсендә яшәү. **Человек с богатым внутренним содержанием** — рухи яктан бай кеше.

**СОДЕРЖА'НКА** *ж. устар.*— сөяркә, содержанка (буржуаз җәмгыятьтә: берәр ир хисабына яшәүче уйнашчы хатын).

**СОДЕРЖА'ТЕЛЬ** *м.*, **СОДЕРЖА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. устар.*— хуҗа, тотучы; *содержатель ресторана* — ресторан тотучы.

**СОДЕРЖА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — бай эчтәлеклелек, бай эчтәлекле булу.

**СОДЕРЖА'ТЕЛЬНЫЙ** — **1.** бай эчтәлекле; *содержательная статья* — бай эчтәлекле мәкалә; **2.** төпле, рухи яктан бай; *содержательный человек* — рухи яктан бай кеше.

**СОДЕРЖА'ТЬ** *несов.*— **1.** асрау, тәрбияләү; *содержать семью* — семьяны асрау; *кроликов содержат в клетках* — куяннарны читлекләрдә асрыйлар; **2.** тоту; *содержать штат служащих* — хезмәткәрләр штаты тоту; *содержать под арестом* — ябып тоту; *содержать в чистоте* — чиста (итеп)

тоту; 3. ...-да (бар); *гектограмм содержит сто граммов* — гектограммда йөз грамм; *сёмга содержит много жира* — сёмгада май бик күп була; *книга содержит в себе много полезных сведений* — китапта бик күп файдалы мәгълүматлар бар. ◇ **Содержать в тайне или в секрете** — сер итеп саклау.

**СОДЕРЖА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. тәэмин ителү; *учащиеся-стипендиаты содержатся на счёт государства* — стипендия алып укучылар дәүләт хисабына тәэмин ителәләр; 2. тотылу, асралу; *кролики содержатся в клетках* — куяннар читлекләрдә асралалар; 3. булу; *в бочёнке содержится около 20 литров бензина*— мичкәдә 20 литр чамасы бензин бар; *в этой книге содержится ряд полезных сведений* — бу китапта күп кенә файдалы мәгълүмат бар; 4. *страд.* тотылу; *дом содержится в чистоте* — өй чиста тотыла; 5. *страд.* саклану; *молоко содержится в погребе* — сөт кар базында саклана.

**СОДЕРЖИ'МОЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— эчендәгесе, эчендә булганы, эчендәге нәрсә, эчендә булган нәрсә; *вылить всё содержимое бутылки* — шешәнең эчендә булганның барын да агызу (бушату).

**СОДЕРЖИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. спец.*— сыем, сыйдырыш.

**СОДЕ'ЯТЬ** *сов. книж. устар., теперь ритор.*— ясау, эшләү, кылу; *содеять преступление* — җинаять кылу.

**СОДЕ'ЯТЬСЯ** *сов. книж. устар., теперь ритор.*— булу; *что это с ним содеялось?* — ни булган икән аңа?

**СОДОВА'Р** *м. спец.*— сода кайнатучы (белгеч).

**СОДОВАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— сода кайнату.

**СО'ДОВЫЙ** — 1. содалы; *содовая вода* — содалы су; 2. сода ...-ы; *содовый раствор* — сода эремәсе; 3. сода ...-ы; сода кайнату ...-ы, сода эшләп чыгара торган; *содовый завод* — сода заводы.

**СОДОКЛА'Д** *м.*— содоклад, өстәмә доклад.

**СОДОКЛА'ДЧИК** *м.*— содокладчы, өстәмә доклад ясаучы.

**СОДОЛЖНИ'К** *м. право, спец.*— бурычташ.

**СОДО'М** *м. мн.* нет — 1. *разг. шутл.* ыгы-зыгы, гауга, шау-шу, кычкырыш; чиктән тыш зур тәртипсезлек; 2. *устар.* шаушу килеп торган төркем. ◇ **Содом и Гоморра** *ритор.*— 1. мәхшәр; ата улны, ана кызны белми; 2. фәхеш, гыйш-гашрәт.

**СОДО'МИТЬ** *несов. просторечн. шутл.*— ыгы-зыгы килү, шау-шу күтәрү, шау-шу килү, гауга күтәрү; кычкырышу, ызгышу.

**СОДО'МСКИЙ** *книж. устар.*— гөнаһлы, бозык, җинаятьле.

**СОДРА'ТЬ** *сов.*—1. каезлау, каезлап алу (кайрысын), (курыс) төшерү; *содрать кору с дерева* — агачның кайрысын каезлау; 2. тунау, тунап алу; *содрать шкуру* — тирене тунау; 3. суйдыру, суйдырып алу; тырнату; *содрать кусочек кожи* — тирене суйдыру; 4. *разг.* кубарып алу, суеп алу, тырнап алу; *содрать прыщик* — сыткыны тырнап алу; 5. *разг. неодобр.* талау, тунау, каеру (югары хак алу, кыйммәт бәягә сату, взятка алу h. б. мәгънәләрдә).

**СОДРА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— суелу, тырналу, суйдырылу; *кусочек кожи содрался* — аз гына тиресе суелган.

**СОДРОГА'НИЕ** *ср. книж.*—1. (*действие*) к. содрогнуться; 2. *только ед.* тетрәнү, калтырану; *нельзя читать без содрогания о зверствах фашизма* — фашизмның ерткычлыклары турында тетрәнмичә укып булмый.

**СОДРОГА'ТЬСЯ** *несов. книж.*—1. калтырау, калтырану, тетрәү; 2. к. содрогнуться.

**СОДРОГНУ'ТЬСЯ** *сов. книж.*— 1. тетрәп китү, селкенеп китү; 2. тетрәнеп китү; дерт итеп китү, калтыранып китү, дерелдәп китү.

**СОДРУ'ЖЕСТВО** *ср. книж.*—1. үзара дуслык, үзара бердәмлек; *содружество социалистических наций* — социалистик милләтләрнең үзара дуслыгы; 2. дуслык җәмгыяте, дуслар төркеме.

**СО'ЕВЫЙ** —1. соя ...-ы; *соевые бобы* — соя борчаклары; *соевое масло* — соя мае (соядан чыгарылган май); 2. соялы; *соевый шоколад* — соялы шоколад.

**СОЕДИНЕ'НИЕ** *ср. книж.*—1. *только ед.* (*действие*) к. соединить, соединиться; 2. тоташтырылган жир, бәйләнгән (төенләнгән) жир; *верёвка оборвалась на самом соединении* — бау төенләнгән жиреннән өзелде; 3. *воен.* соединение, берләшмә; 4. *хим.* кушылма; *химическое соединение* — химик кушылма; 5. *только мн. мат.* тоташтырмалар; 6. *астр.* бер юнәлештә булу (ике планетаның яки бер планета белән кояшның бер үк якта һәм озынлыкта булуы).

**СОЕДИНЁННЫЙ** —1. тоташтырылган, кушылган, берләштерелгән; 2. кушма ...; *Соединённые Штаты Америки* — Америка Кушма Штатлары; *соединённый флот двух держав* — ике державаның кушма флоты.

**СОЕДИНИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— кушылучанлык, кушыла алу; берләшүчәнлек, берләшә алучанлык.

**СОЕДИНИ'МЫЙ** *книж.*— кушыла торган, кушылучан, кушыла ала торган; берләшүчән, берләшә алучан; тоташтырыла торган.

**СОЕДИНИ'ТЕЛЬ** *м. тех.*— тоташтыргыч, беркеткеч, беректергеч.

**СОЕДИНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*—тоташтыргыч ..., тоташтыру ...-ы, беректергеч ..., беректерү ...-ы; беркеткеч ..., беркетү...-ы; *соединительные материалы* — тоташтыру материаллары (мәсәлән, келәй, винт h. б.). ◇ **Соединительный союз** *грам.*— бәйләүче теркәгеч. **Соединительная ткань** *биол.*— тоташтыргыч тукыма.

**СОЕДИНИ'ТЬ** *сов.*—1. берләштерү, кушу; *соединить силы* — көчләрне берләштерү; 2. тоташтыру, тоташтырып кую; *соединить проволоку* — тимер чыбыкны тоташтыру; 3. бәйләү, бәйләп кую, төенләп кую; *соединить концы верёвки* — бауның очларын бәйләп кую; 4. *перен.* бер үк вакытта булу, берләштерү, бергә кушу; *соединить храбрость с хладнокровием* — бер үк вакытта кыю һәм салкын канлы булу. ◇ **Соединить**

**города телефоном** — шәһәрара телефон үткәрү, шәһәрләр арасында телефон үткәрү. **Соединить любящих браком** — гашыйкларны өйләндерү.

**СОЕДИНИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. кушылу; *масло может соединиться с водою посредством щелочи* — май суга селте ярдәмендә кушыла ала; 2. берләшү; *войска соединились* — гаскәрләр берләште; 3. бәйләнү, тоташу; *концы верёвок соединились* — бауларның очлары тоташты; 4. (бер үк вакытта) булу, берләшү, кушылу; *в нём соединились разнородные способности* — аның төрле нәрсәгә сәләте бар.◇ **Соединиться по телефону** — телефоннан сөйләшү. **Берега соединились посредством моста** — ике як ярны күпер тоташтырды. **Соединиться браком** — өйләнешү.

**СОЕДИНЯ'ТЬ** *несов.*— к. соединить.

**СОЕДИНЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. соединиться; 2. *страд.* кушылу, берләштерелү; тоташтырылу, тоташтырып куелу, бәйләп куелу, төенләп куелу.

**СОЖАЛЕ'НИЕ** *ср. книж.*— 1. кайгыру, үкенү, үкенеч; *сожаление об ушедшей молодости* — үтеп киткән яшьлек турында кайгыру; 2. аяу, жәлләү, кызгану; кайгысын уртаклашу; *сожаление к чужому горю* — кешенең кайгысын уртаклашу.◇ **К сожалению** или **к крайнему** (великому, глубокому) **сожалению** *ввод. сл.*— кызганычка каршы, (бик зур) үкенечкә каршы, аянычка каршы.

**СОЖАЛЕ'ТЬ** *несов.*—1. кызгану, жәлләү; *сожалеть о напрасно потерянном времени* — әрәмгә киткән вакытны кызгану; 2. үкенү; *очень сожалею, что нам не удалось повидаться* — күрешә алмавыбызга бик үкенәм.

**СОЖИ'ТЕЛЬ** *м.*— 1. бергә торучы, бер бүлмәдә торучы, өйдәш, бүлмәдәш; *мой сожитель по комнате* — минем белән бер бүлмәдә торучы (кеше); 2. *устар.* (*супруг*) ир; 3. *устар.* никахсыз ир.

**СОЖИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*—1. к. сожитель 1; 2. *устар.* (*супруга*) хатын; 3. *устар.* никахсыз хатын.

**СОЖИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет —1. *книж.* бергә тору; бергә яшәү; *сожительство нескольких человек в одной комнате* — берничә кешенең бер бүлмәдә бергә торуы; 2. *устар.* (бергә) тору (ир белән хатын булып яшәү).

**СОЖИ'ТЕЛЬСТВОВАТЬ** *несов.*—1. *книж.* бергә тору, өйдәш булу, бергә яшәү; 2. *устар.* (бергә) тору (ир белән хатын булып яшәү), ирле-хатынлы булып яшәү.

**СОЖИ'ТИЕ** *ср. мн.* нет. *книж. устар.*— к. сожительство.

**СОЖРА'ТЬ** *сов. простореч. вульг.*— тыгынып бетерү, бүсеп бетерү, комсызланып ашап бетерү.

**СОЗВА'ТЬ** *сов.*— чакыру, жыю; *созвать гостей* — кунаклар чакыру; *созвать митинг* — митинг жыю.

**СОЗВЕ'ЗДИЕ** *ср. астр.*— йолдызлык, йолдызлар төркеме.

**СОЗВОНИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— телефоннан шалтыратып сөйләшү, телефон аркылы сөйләшү.

**СОЗВУ'ЧИЕ** *ср.*—1. *муз.* аһәңдәшлек; 2. *устар.* авазлар охшашлыгы; авазларның аһәңдәшлеге.

**СОЗВУ'ЧНЫЙ** *книж.*— 1. *муз. устар.* аһәңдәш, охшаш; 2. *перен. книж.* үзара охшаш; *созвучные звуки* — үзара охшаш авазлар; 3. *книж.* ярашлы, яңгырашлы, муафикъ, туры килә торган, аваздаш; *литература, созвучная эпохе* — заманына туры килә торган әдәбият.

**СОЗДАВА'ТЬ** *несов.*— к. создать.

**СОЗДАВА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. создаться; 2. *страд.* булдырылу, тудырылу, барлыкка китерелү; төзелү, оештырылу, ижат ителү.

**СОЗДА'НИЕ** *ср.*—1 *только ед.* (*действие*) к. создать; 2. әсәр; *создания художника* — художникның әсәрләре; 3 *разг.* зат, кеше; *милое создание* — сөйкемле кеше.

**СОЗДА'ТЕЛЬ** *м.*—1. булдыручы, тудыручы, барлыкка китерүче; *создатель теории* — теорияне тудыручы; 2. төзүче; *В. И. Ленин — создатель Коммунистической партии* — В. И. Ленин — Коммунистлар партиясен төзүче ул; 3. ижатчы, ижат итүче; *Чехова (Л. Толстой) любит отечески,— в этой любви чувствуется гордость создателя* (М. Горький) — (Л. Толстой) Чеховны аталарча ярата,— бу мәхәббәттә ижатчы(ның) горурлыгы сизелеп тора; 4. *книж. устар. рел.* тәңре, алла, яратучы.

**СОЗДА'ТЕЛЬНИЦА** *ж.*— к. создатель 1.

**СОЗДА'ТЬ** *сов.*— 1. булдыру, тудыру, барлыкка китерү; *создать благоприятные условия для работы* — эш өчен уңай шартлар булдыру; *создать новую теорию* — яңа теория тудыру; 2. төзү, оештыру; *создать государство* — дәүләт төзү; 3. ижат итү; *создать произведение искусства* — сәнгать әсәре ижат итү.◇ **Создать почву для развития науки** — фән үсешенә нигез салу (жирлек әзерләү).

**СОЗДА'ТЬСЯ** *сов.*— туу, барлыкка килү.

**СОЗЕРЦА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. филос.*— күзәтелүчәнлек, күзәтелә алучанлык, күзәтә алырлык булу.

**СОЗЕРЦА'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *книж.* (*действие*) к. созерцать; 2. *книж.* хыялга бирелү, хыялга чуму; *человек, склонный к созерцанию* — хыялга бирелүчән кеше; 3. *филос.* к. интуиция 1.

**СОЗЕРЦА'ТЕЛЬ** *м. книж.*—1. *устар.* күзәтүче; *созерцатель тайн природы* — табигать серләрен күзәтүче; 2. *ирон. неодобр.* пассив күзәтүче; хыялга бирелүчән кеше, хыялга чумучан кеше.

**СОЗЕРЦА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *устар.* тирәнтен күзәтүчәнлек, үтә күрүчәнлек; 2. *неодобр.* пассив күзәтүчәнлек; хыялга бирелүчәнлек, хыялга (уйга) чумучанлык.

**СОЗЕРЦА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— 1. *устар* тирәнтен күзәтүчән, үтә күрүчән; *созерцательный ум* — тирәнтен күзәтүчән акыл; 2. *неодобр.* пассив, хыялга бирелеп ...; *созерцательное отношение к действительности* — чынбарлыкка пассив мөнәсәбәт;

*созерцательная жизнь* — хыялга бирелеп яшәү.

**СОЗЕРЦА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— **1.** пассив күзәтү; *созерцать природу* — табигатьне пассив күзәтү; **2.** *ритор.* күрү, үтә күрү, ачык күрү; *созерцать тайные пружины событий* — вакыйгаларның яшерен пружиналарын ачык күрү; *созерцать истинную сущность явлений* — күренешләрнең чын асылын күрү.

**СОЗЕРЦА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.*— күзәтелү.

**СОЗИДА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. ритор.*— иҗади, иҗат итү ...-ы, тудыру ...-ы, барлыкка китерү ...-ы, төзү ...-ы; *созидательный процесс* — иҗади процесс.

**СОЗИДА'ТЬ** *несов. книж. ритор.*— к. создать.

**СОЗИДА'ТЬСЯ** *несов. книж. ритор.* — **1.** к. создаться; **2.** *страд.* к. создаваться 2.

**СОЗНАВА'ТЬ** *несов.*— к. сознать.

**СОЗНАВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. сознаться. ◇ **Сознаюсь** *ввод. сл.*— танмыйм, яшермим, дөресен (туры, ачык) әйтәм, дөресен әйтергә тиешмен, ачыктан-ачык әйтергә тиешмен; *сознаюсь, я никак не ожидал этого* — дөресен әйтергә тиешмен, мин моны һич тә көтмәгән идем.

**СОЗНА'НИЕ** *ср. мн.* нет —**1.** (*действие и состояние*) к. сознать; **2.** (*действие*) к. сознаться; **3.** уй, фикер; *неотразимое сознание, что без меня нет счастья ей* (Некрасов) — миннән башка аңар бәхет юк дигән котылгысыз уй; *его угнетало сознание невозможности спасти больного* — авыруны коткарып калу мөмкин түгел дигән фикер аны бик нык борчый иде; 4. аң; *не сознание людей определяет их бытие, а, наоборот, их общественное бытие определяет их сознание* (К. Маркс) — кешеләрнең яшәешен аларның аңы билгеләми, бәлки, киресенчә, аларның аңын иҗтимагый яшәеш билгели; 5. аң, һуш; *больной потерял сознание* — авыру аңын югалтты; *прийти в сознание* — һушына килү.

**СОЗНА'ТЕЛЬНО** *нареч.*—**1.** белә торып, юри; *сознательно обмануть* — белә торып алдау; 2. аңлы (рәвештә); *сознательно относиться к порученному делу* — тапшырылган эшкә аңлы мөнәсәбәттә булу.

**СОЗНА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. аңлылык; *сознательность масс* — массаларның аңлылыгы; 2. аңлы рәвештә эшләнгәнлек, белә торып эшләнгәнлек, белеп эшләнгәнлек; *сознательность поступка* — эшнең аңлы рәвештә эшләнгәнлеге.

**СОЗНА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. аңлы; 2. аңлы рәвештә эшләнгән, аңлы рәвештә..., белә торып..., белеп..., күрәләтә...; *сознательный обман* — күрәләтә алдау; *сознательный поступок* — аңлы рәвештә эшләнгән эш. ◇ **Человек — существо сознательное** — кеше — акыл иясе ул.

**СОЗНА'ТЬ** *сов.* — аңлау, тану, икърар итү; *сознать свой долг* — үз бурычыңны аңлау; *сознать свою вину* — үз гаебеңне тану, икърар итү.

**СОЗНА'ТЬСЯ** *сов.* — тану, икърар итү, ачыктан-ачык әйтеп бирү (сөйләп бирү); *сознаться в своей неправоте* — үзеңнең хаксызлыгыңны тану; *преступник во всём сознался* — җинаятьче бөтен гаебен таныды; *сознаться в своём намерении* — үзеңнең ниятеңне ачыктан-ачык сөйләп бирү. ◇ **Нельзя не** или **надо** (или **должно**) **сознаться** — дөресен генә әйткәндә, ачыктан-ачык әйткәндә, дөресен әйтергә кирәк; *надо сознаться, я этого никак не ожидал* — дөресен әйтергә кирәк, мин моны һич тә көтмәгән идем.

**СОЗОРНИЧА'ТЬ** *сов. разг.* — шуклык эшләп ташлау, шаянлык эшләп ташлау.

**СОЗРЕВА'ТЬ** *несов.* — 1. к. созреть; **2.** пешеп килү, өлгереп килү; *плоды созревают* — җимешләр өлгереп килә.

**СОЗРЕ'ЛЫЙ** *устар.* — пешкән, пешеп җиткән, өлгергән, өлгереп җиткән, җитлеккән.

**СОЗРЕ'ТЬ** *сов.* — **1.** пешү, пешеп җитү, өлгерү, өлгереп җитү; *плоды созрели* — җимешләр өлгерде; **2.** *переч.* (*достигнуть зрелости*) яшькә җитү, буйга җитү, балигъ булу, җитлегү; **3.** *перен.* җитлегү, үсеп җитү; *талант его созрел* — аның таланты үсеп җитте; **4.** *перен.* өлгерү, өлгереп җитү; *план созрел в его уме* — аның башында план өлгереп җитте.

**СОЗЫ'В** *м. мн.* нет — 1. чакыру, җыю; *созыв собрания* — җыелыш җыю; 2. чакырылыш; *Верховный Совет СССР первого созыва* — СССР Верховный Советының беренче чакырылышы.

**СОЗЫВА'ТЬ** *несов.* — к. созвать.

**СОЗЫВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — чакырылу, җыелу.

**СОИЗВОЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. ритор. устар.*, *теперь ирон.* — 1. (*действие*) к. соизволить; 2. теләк.

**СОИЗВО'ЛИТЬ** *сов. книж. ритор. устар. теперь ирон.* — к. соблаговолить.

**СОИЗВОЛЯ'ТЬ** *несов. книж. ритор. устар.*, *теперь ирон.* — к. соизволить.

**СОИЗДА'ТЕЛЬ** *м. офиц.* — нәшердәш, бергә бастырып чыгаручы (мәсәлән, китапны).

**СОИЗМЕРИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. *мат.* үлчәнешлелек, үзара үлчәнешле булу; 2. *перен.* үзара чагыштырып була торганлык.

**СОИЗМЕРИ'МЫЙ** *книж.* — **1.** *мат.* үлчәнешле, үзара үлчәнешле; *соизмеримые величины* — үлчәнешле зурлыклар; 2. *перен.* үзара чагыштырыла алырлык...; *соизмеримые понятия* — үзара чагыштырыла алырлык төшенчәләр.

**СОИМЕ'ННИК** *м.*, **СОИМЕ'ННИЦА** *ж. книж устар.* — адаш, исемдәш.

**СОИМЕ'ННЫЙ** *книж. устар.* — адаш ..., исемдәш ... .

**СОИСКА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж офиц.*: **на соискание** — алу өчен; *диссертация на соискание учёной степени доктора наук* — фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсен алу өчен (язылган) диссертация.

**СОИСКА'ТЕЛЬ** *м.*, **СОИСКА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. книж. офиц.* — конкурста катнашучы; (гомумән үзенең) хезмәтен бәяләүгә бирүче.

**СОИСКА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет., *книж. офиц.* — конкурста катнашу; (гомумән үзеннең) хезмәтеңне бәяләүгә бирү.

**СО'ИКА** *ж. зоол.* — күкшә (кош).

**СО'ЙМА** *ж. спец.* — сойма (бер мачталы, палубалы йөк судносы).

**СОЙТИ'** I *сов.* — 1. төшү; *сойти с лестницы* — баскычтан төшү; *сойти с лошади на землю* — аттан җиргә төшү; 2. кайту, китү; *вода сошла с лугов* — болыннардан су кайткан; 3. кубу, кубып төшү; *кожа сошла с пальца* — бармакның тиресе кубып төшкән; 4. чыгу, читкә чыгу; *сойти с дороги* — юлдан читкә чыгу; 5. төшү, чыгу; *вагон сошёл с рельсов* — вагон рельстан төшкән. ◇ **Сойти в могилу** — гүргә керү (үлү). **Сойти на нет** — юкка чыгу. **Сойти с ума** — акылдан язу, акылдан шашу.

**СОЙТИ'** II *сов. разг.* — ярау, урынына ярау, урынына ярарлык булу; *сойти за настоящего актёра* — чын актёр урынына ярау. ◇ **Сойдёт и так** — болай да ярар. **Всё сошло хорошо** — барысы да яхшы үтте. **Сойти с рук** — к. рука.

**СОЙТИ'СЬ** *сов.* — 1. очрашу; *сошлись на перекрёстке* — чатта очраштык; 2. очрашу, җыелу; *сошлись знакомые и друзья* — таныш-белешләр һәм дуслар җыелды; 3. *перен.* дуслашу, дуслашып китү, якынлашу; *мы сошлись ещё в школьные годы* — без мәктәптә укыганда ук дуслашкан идек; 4. *(вступить в половое сожительство)* тора башлау; бергә тора башлау; 5. (фикерләре, сүзләре һ. б.) туры килү; *сошлись во мнениях* — фикерләре туры килгән; *сошлись характерами* — характерлары туры килгән; 6. килешү; *не сошлись в цене* — бәясендә килешмәдек; 7. җитү; *пояс не сошёлся* — билбау җитмәде (кыска булып чыкты); 8. якынлашу, бер-берсенә якын килү, якын булу; *утёсы близко сошлись и образовали узкое ущелье* — кыяташлар бер-берсенә якын булу сәбәпле, тар гына тарлавык барлыкка килгән; 9. *разг.* уңу, барып чыгу; *дело у них не сошлось* — аларның эшләре барып чыкмады. ◇ **Свет не клином сошёлся** — дөнья аңа гына терәлмәгән, дөнья аңардан гына тормый.

**СОК** *м.* — 1. сок, су; сыгынты; *выжать сок из винограда* — виноград согын сыгу; *ягодный сок* — җиләк суы; *желудочный сок* — ашказаны суы; 2. сок (а. төрле үсемлекләрдән бүленеп чыга торган сумала, сагыз кебек сыек матдәләр; б. *спец.* төрле үсемлекләрдән табыла һәм су кушып техникада кулланыла торган ябышучан масса; в. *тех.* тире дуплау өчен кулланыла торган матдәләр эремәсе; г. *горн.* руда һәм металл эреткәндә барлыкка килә торган шлак, көек; д. *спец.* сыек известь массасы); 3. *только ед. перен. разг.* каймак; иң яхшы катламы; *сок умной молодежи* (Грибоедов) — акыллы яшьләрнең каймагы. ◇ **Вариться в (своём) собственном соку** — үз казанында кайнау, үз маенда куырылу. **В (самом или полном) соку** — 1. *(о растениях)* гөрләп үскән чагы; 2. *(о людях)* яшьнәгән чагы, янып торган вакыты, иң таза чагы. **Выжать (все) соки** или **высосать (все) соки** или **давить сок** — җелеген суыру. **Соком выйти** *разг.* — авырга төшү, авырлык белән килү.

**СОКВАРТИРА'НТ** *м.*, **СОКВАРТИРА'НТКА** *ж. офиц.* — квартирдаш, квартирда бергә торучы, бер квартирда яшәүче, бер квартирда торучы.

**СОКОВО'Й** и **СО'КОВЫЙ**: **соковые краски** — соклы буяулар; **соковый ход** *тех.* — бернічә чанда (тире) дуплау процессы; **соковая подошва** — калын һәм йомшак олтан.

**СО'КОЛ** I *м.* — лачын. ◇ **Гол, как сокóл** *разг.* — үзе дә күзе генә, шыр ялангач (ярлы мәгънәсендә). **Гол, но сокóл** *разг. шутл.* — ярлы булса да, үз бәясен (кадерен) белә; хәерче булса да, үз бәясен (кадерен) белә; ярлы тәкәббер.

**СО'КОЛ** II *м.* — 1. *истор.* сокол (зур тимер лом — стеналар тишә торган корал сыйфатында һәм тау эшләрендә кулланылган); 2. *обл.* к. трамбовка 2.

**СОКОЛЁНОК** *м.* (*мн.* соколя́та) — лачын баласы.

**СОКОЛЕ'Ц** *м. спец. обл.* — к. соколок 1, 2.

**СОКО'ЛИЙ** *устар.* — к. соколиный 1, 2.

**СОКО'ЛИК** *м.* — 1. *нар.-поэт.* лачынкай, лачын; 2. *преимущ. мн. ирон. простореч.* егетләр, лачыннар, арсланнар; 3. *преимущ. мн. простореч. (при обращении к лошадям)* малкайлар, лачыннарым.

**СОКОЛИ'НЫЙ** — 1. лачын ...-ы; *соколиный лёт* — лачын очышы; 2. лачын белән...; *соколиная охота* — лачын белән аулау; 3. *перен.* лачын ...-ы, лачынча ...; *соколиный взгляд* — лачынча караш; 4. *мн. в знач. сущ.* лачынчалар семьялыгы.

**СОКОЛИ'ХА** *ж. спец.* — ана лачын.

**СОКОЛО'К** *спец. обл.* — 1. атның алгы аягындагы кан тамыры; 2. баш бармакның кара тамыры, венасы; 3. баш бармак белән имән бармак арасындагы озынча чокырчык; 4. соколок (штукатурчылар эшендә кулланыла торган тоткалы такта).

**СОКОЛООБРА'ЗНЫЕ** *только мн. зоол.* — лачынсыманнар.

**СОКО'ЛЬНИК** *м. истор.* — лачынчы (1. лачын аулаучы; 2. борынгы Русьта — патша сараенда ау кошларын тәрбияләүче һәм өйрәтүче аучы).

**СОКО'ЛЬНИЧИЙ** *м. истор.* — лачынчылар башлыгы (борынгы Русьта — патша сараенда лачын белән аулауда җитәкче ролен үтәүче бояр).

**СОКОЛЯ'ТНИК** *м.* — лачынчы, лачын һәвәскәре (лачын асрау белән мавыгучы)

**СОКРАТИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *книж.* кыскартылу(чанлык); 2. *физиол.* кыскару(чанлык).

**СОКРАТИ'МЫЙ** *книж.*— кыскартырлык, кыскартып була торган.

**СОКРАТИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физиол.* — к. сократимость 2.

**СОКРАТИ'ТЕЛЬНЫЙ** — кыскарту ...-ы; *сократительный приём* — кыскарту алымы; *сократительные волоконца* (биол.) — кыскарту җепселләре.

**СОКРАТИ'ТЬ** *сов.* — 1. кыскарту, киметү; *редактор сократил статью* — редактор мәкаләне кыскарткан; *сократить свои расходы* — расходларыңны киметү; *сократить дроби*— вакланманы кыскарту; 2. *разг. (уволить со службы)* кыскарту, штат кимү сәбәпле эштән чыгару; 3. *перен. простореч. фам.* телен кыскарту, кысу; *я этого не спущу... я тебя сокращу, мой друг* (М. Горький) — мин моны болай гына калдырмам... мин, туганкай, синең телеңне кыскартырмын.

**СОКРАТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. кыскару, кимү; *расстояние сократилось* — ара кыскарды; *дни сократились* — көннәр кыскарды; *расходы сократились* — расходлар кимеде; 2. *разг.* кысылу; *придётся нам в этом месяце сократиться* — бу айда безгә кысылырга туры килер; 3. *простореч. фам.* туктау, кысылу.

**СОКРАЩА'ТЬ** *несов.* — к. сократить.

**СОКРАЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. сократиться; 2. *страд.* кыскартылу, киметелү; 3. *страд.* кыскартылу, штат кимү сәбәпле чыгарылу.

**СОКРАЩЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед. (действие)* к. сократить; 2. *(состояние)* к. сократиться 1; 3. кыскартма; *слово „рация"— сокращение слова „радиостанция"* — „рация" сүзе „радиостанция" сүзенең кыскартмасы; *список условных сокращений* — шартлы кыскартмаларның исемлеге.

**СОКРЕДИТО'Р** *м. торг. фин.*—кредитордаш (икенче бер кеше яки учреждение белән бергә кредит бирүче кеше яки учреждение).

**СОКРОВЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— яшеренлек, сер итеп саклангалык, сер итеп саклану, күңел түрендә булу.

**СОКРОВЕ'ННЫЙ** *книж.*— яшерен, сер итеп саклана торган, сер итеп сакланган, күңел түрендәге; *сокровенные мысли* — яшерен уйлар.

**СОКРО'ВИЩЕ** *ср. книж.* — хәзинә, мал, байлык. ◇ **Ни за какие сокровища** *разг.*— һичбер вакытта да, үзе кадәр алтын бирсә дә.

**СОКРО'ВИЩНИЦА** *ж. книж.*— 1. казна (хәзинәләр саклану урыны, кыйммәтле нәрсәләр саклану урыны); 2. хәзинә.

**СОКРУША'ТЬ** *несов. книж.* — к. сокрушить.

**СОКРУША'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* ачыну, көенү, хәсрәтләнү, хәсрәт чигү, кайгыру; *о чём вы сокрушаетесь?* — сез нәрсә турында хәсрәтләнәсез? 2. *страд. книж.* тар-мар ителү, юк ителү.

**СОКРУШЕ'НИЕ** I *ср.* — кайгы, көенеч, хәсрәт.

**СОКРУШЕ'НИЕ** II *ср.* — к. сокрушить I.

**СОКРУШЁННЫЙ** — кайгылы, хәсрәтле, ачынулы, көенгән.

**СОКРУШИ'ТЕЛЬ** *ж. книж. ритор.* — тар-мар итүче, җимерүче, юк итүче.

**СОКРУШИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — тар-мар итәрлек булу, җимерә торган булу, юк итәрлек булу, җимергеч булу.

**СОКРУШИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — тар-мар итә торган, җимерә торган, юк итә торган, җимергеч.

**СОКРУШИ'ТЬ** I *сов. книж. ритор.* — тар-мар итү, җимерү, юк итү, бәреп төшерү.

**СОКРУШИ'ТЬ** II *сов. книж.* — ачындыру, көендерү, хәсрәткә төшерү; *это известие сокрушило его* — бу хәбәр аны хәсрәткә төшерде.

**СОКРЫ'ТЫЙ** *книж. устар.* — 1. *офиц., поэт.* яшерелгән; 2. *офиц., поэт.* яшеренгән; 3. *поэт.* яшерен, сер итеп сакланган, сер итеп саклана торган, күңел түрендәге.

**СОКРЫ'ТЬ** *сов. книж. устар. офиц.* или *поэт.* — яшерү, качыру.

**СОКРЫ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар. поэт.*— яшеренү, качу.

**СОЛГА'ТЬ** *сов.* — ялганлау, ялганлап кую, ялган сөйләү, алдау.

**СОЛДА'Т** *м.* — солдат.

**СОЛДА'ТКА** *ж.* — солдат хатыны.

**СОЛДАТНЯ'** *ж. собир. простореч. презрит.* — солдатлар.

**СОЛДА'ТСКИЙ** — солдат ...-ы, солдатлар ...-ы; *солдатская форма* — солдат формасы.

**СОЛДА'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.* — 1. к. солдатчина 2; 2. *собир.* солдатлар.

**СОЛДА'ТУШКИ** *ед.* нет, *простореч. устар.* — солдаткайлар.

**СОЛДА'ТЧИНА** *ж. мн.* нет — 1. *истор. (рекрутский набор)* солдатка алу; 2. *(солдатская служба)* солдат хезмәте, солдатта хезмәт итү, солдатлык.

**СОЛДАТЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир. простореч. пренебр.* — к. солдатня.

**СОЛДАФО'Н** *м. разг. презрит.* — солдафон (тупас, культурасыз гаскәри).

**СОЛДАФО'НСКИЙ** *разг. презрит.* — солдафон ...-ы; солдафонга хас, солдафонлык...-ы.

**СОЛДАФО'НСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. презрит.* — солдафонлык.

**СОЛЕВА'Р** *м. спец.* — тоз чыгаручы, тоз кайнатучы (эшче), тоз кайнату белгече.

**СОЛЕВАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — (диңгез яки тозлы күл суыннан) тоз табу, тоз чыгару, тоз кайнату.

**СОЛЕВА'РЕННЫЙ, СОЛЕВА'РНЫЙ** —

тоз чыгару (табу) ...-ы, тоз кайнату ...-ы; *солеваренный завод* — тоз кайнату заводы.

**СОЛЕВА'РНИЦА** *ж. спец.* — к. солеварня.

**СОЛЕВА'РНЫЙ** *спец.* — к. солеваренный.

**СОЛЕВА'РНЯ** *ж. спец.* — тоз табу урыны, тоз чыгару урыны.

**СОЛЕВО'Й** — 1. тоз ...-ы; *солевые пятна на шкуре* — тиредәге тоз таплары; 2. тоз табу ...-ы, тоз чыгару ...-ы; *солевые разработки* — тоз чыгару урыннары.

**СОЛЕЛО'МНЯ** *ж. спец.* — таш тоз табу урыны, таш тоз чыгару урыны.

**СОЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. (действие)* к. солить 1, 2; 2. *разг.* тозланган яшелчәләр, тозлап куелган яшелчәләр.

**СОЛЕНО'ИД** *м. тех. физ.* — соленоид (электр тогы үткәргәндә тирәсендә магнит кыры барлыкка килә торган тимер чыбыктан ясалган спираль).

**СОЛЁНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тозлылык.

**СОЛЁНЫЙ** — 1. тозлы; *солёные озёра* — тозлы күлләр; 2. тозланган, тозлы; *солёные огурцы* — тозлы кыяр; 3. *перен.* суганлыборычлы, оятсыз; *солёный анекдот* — оятсыз анекдот.

**СОЛЕПРОМЫ'ШЛЕННИК** *м. дореволь.* — тоз промышленнигы (тоз табу предприятиесе хуҗасы).

**СОЛЕПРОМЫ'ШЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — тоз табу (чыгару) промышленносте.

**СОЛЕПРОМЫ'ШЛЕННЫЙ** *спец.* — тоз табу ...-ы; *солепромышленное предприятие* — тоз табу предприятиесе.

**СОЛЕЦИ'ЗМ** *м. лингв. лит.* — солецизм (синтаксик хата, әдәби телне бозып сөйләү).

**СОЛИДАРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. солидаризироваться.

**СОЛИДАРИЗИ'РОВАТЬСЯ, СОЛИДАРИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — солидарлашу, (фикергә) кушылу, теләктәшлек белдерү; *солидаризоваться с чьим-н. мнением* — берәр кешенең фикеренә кушылу.

**СОЛИДА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. солидарлык, фикердәшлек, теләктәшлек; бердәмлек; 2. *право* солидарлык, уртак җаваплылык.

**СОЛИДА'РНЫЙ** *книж.* — 1. *в знач. сказ.* фикергә кушылу, теләктәшлек күрсәтү; *я с вами вполне солидарен* — мин сезнең фикерегезгә тулысынча кушылам; 2. *только полн. ф-мы право* солидар, уртак; *солидарная ответственность* — уртак җаваплылык.

**СОЛИ'ДНИЧАТЬ** *несов. разг.* — олысымаклану, җитдилек күрсәткән булып маташу.

**СОЛИ'ДНО** *нареч.* — 1. ышанычлы итеп, нык; 2. җитди; *вести себя солидно* — үзеңне җитди тоту; 3. күп, күп кенә, шактый гына; *солидно зарабатывать* — күп (күп кенә) акча эшләү.

**СОЛИ'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *книж.* төплелек, зурлык; *солидность знаний* — белемнәрнең зурлыгы (зур белемле булу); 2. җитдилек; *ему не хватает солидности* — аңар җитдилек җитми.

**СОЛИ'ДНЫЙ** — 1. ышанычлы, нык; *солидная постройка* — нык каралты; 2. нигезле, төпле; *солидные познания* — төпле белемнәр; 3. җитди; *солидный вид* — җитди кыяфәт; 4. *перен.* җитди, төпле; *солидный человек* — төпле кеше; *солидный журнал* — җитди журнал; 5. *разг.* шактый зур, байтак; *солидная сумма* — шактый зур сумма. ◇ **Человек солидных лет** *разг.* — олы яшьтәге кеше.

**СОЛИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — тозлау...-ы; *солильный цех* — тозлау цехы.

**СОЛИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — тозлаучы; *солильщик рыбы* — балык тозлаучы.

**СОЛИПСИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — солипсизм (идеализмның бер төре).

**СОЛИПСИ'СТ** *м.* — солипсист, солипсизм яклы кеше, солипсизм тарафдары.

**СОЛИПСИ'ЧЕСКИЙ** *филос.* — солипсистик, солипсизм...-ы; *солипсическая философия Беркли и Юма* — Беркли һәм Юмның солипсистик философиясе.

**СОЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. театр муз.* — ялгыз җырлау; (музыка коралында) ялгыз уйнау; (балетта) ялгыз бию.

**СОЛИ'СТ** *м. театр. муз.* — солист (ялгыз җырчы, биюче яки музыка коралында уйнаучы).

**СОЛИ'СТКА** *ж. театр. муз.* — солистка (ялгыз җырчы, биюче яки музыка коралында уйнаучы хатын-кыз).

**СОЛИТЕ'Р** *м. мин.* — солитер (эре бриль-янтның бер төре).

**СОЛИТЁР** *м. зоол.* — солитёр, тасма суалчан.

**СОЛИ'ТЬ** *несов.* — 1. тозлау; *солить грибы* — гөмбә тозлау; *солить рыбу* — балык тозлау; 2. тоз салу; *солить суп* — ашка тоз салу; 3. *разг. фам. редко* к. насолить 3.

**СОЛИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — тозлану, тоз салыну.

**СО'ЛКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. солить 1.

**СО'ЛКИЙ** *спец.* — яхшы тозлый торган; *солкая соль* — яхшы тозлый торган тоз.

**СО'ЛНЕЧНО** — 1. *нареч.* шат; 2. *безл. в знач. сказ.* көн кояшлы.

**СО'ЛНЕЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — кояш яктысы, кояш белән яктыртылганлык.

**СО'ЛНЕЧНЫЙ** — 1. *только полн. формы* кояш ...-ы; *солнечная система* — Кояш системасы; 2. кояшлы; *солнечный день* — кояшлы көн; 3. *перен. книж.* кояшлы, шатлыклы, шат, күтәренке; *солнечное настроение* — шат күңел.

**СОЛНОПЁК** *м. мн.* нет, *разг.* — к. солнцепёк.

**СО'ЛНЦЕ** *ср.* — кояш. ◇ **До солнца** *разг.* — кояш чыкканчы.

**СОЛНЦЕПЁК** *м. мн.* нет — кояш кызуы, кояш кыздыра торган җир (урын).

**СОЛНЦЕСТОЯ'НИЕ** *ср. астр.* — кояш

торышы (җәйгесе — 22 июньдә, кышкысы — 22 декабрьда була).

**СО'ЛО** — 1. соло (а. *ср. нескл. муз.* бер тавыш яки бер музыка коралы өчен язылган музыкаль әсәр яки аның бер өлеше; б. *ср. нескл. театр.* бер кеше тарафыннан башкарыла торган танец); 2. *нареч.* ялгыз; *петь соло* — ялгыз җырлау. ◇ **Соло-вексель** *фин.* — соло-вексель (бер кеше җаваплы булган һәм бер имза куелган вексель).

**СОЛОВЕ'Й** *м.* (*мн.* соловьй) — сандугач, былбыл.

**СОЛОВЕ'ТЬ** *несов.* — 1. *спец.* сары төскә керә башлау, сары төскә керү; 2. *перен. простореч. (о глазах)* тону; 3. *перен. простореч. (о человеке)* мәлҗерәү.

**СОЛО'ВКА** *ж. обл.* — ана сандугач.

**СОЛО'ВЫЙ** *спец.* — сары (ат төсе).

**СОЛОВЬЁНОК** *м.* (*мн.* соловьята) — сандугач баласы.

**СОЛОВЬИ'НЫЙ** — сандугач ...-ы; *соловьиные трели* — сандугач чутылдавы.

**СОЛОВЬИ'ХА** *ж.* — к. соловка.

**СО'ЛОД** *м.* — салат (шыттырып киптерелгән арыштан, арпадан һ. б. эре итеп тарттырылган он; сыра кайнатуда кулланыла).

**СОЛОДЕ'ТЬ** *несов. обл.* — салатлану.

**СОЛОДИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — салат ясый торган.

**СОЛОДИ'ЛЬНЯ** *ж. спец.* — салат ясый торган урын.

**СОЛОДИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — салатчы, салат ясаучы (шыттырып киптерелгән орлыктан).

**СОЛОДИ'ТЬ** *несов. спец.* — 1. (салат ясау өчен) шыттыру; *солодить ячмень* — арпаны салат ясау өчен шыттыру; 2. төчетү; *солодить тесто* — камырны төчетү.

**СОЛОДИ'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — 1. (салат ясау өчен) шыттырылу; 2. төчетелү.

**СОЛО'ДКА** *ж. мн.* нет, *бот.* — татлы тамыр, төче тамыр.

**СОЛОДКО'ВЫЙ** *бот.*: **солодковый корень** — татлы тамыр.

**СОЛОДО'ВЕННЫЙ** *спец.* — салат ...-ы; салат ясау ...-ы; *солодовенный завод* — салат заводы.

**СОЛОДО'ВНИК** *м. спец.* — салат заводы эшчесе.

**СОЛОДО'ВНЯ** *ж. спец.* — к. солодильня.

**СОЛОДО'ВЫЙ** *спец.* — салат...-ы; *солодовый квас* — салат куасы.

**СОЛОЖЁНЫЙ** *спец.* — төчетелгән; *соложёное тесто* — төчетелгән камыр.

**СОЛО'МА** *ж. мн.* нет — салам.

**СОЛОМА'ТА** *ж.* — к. саламата.

**СОЛО'МЕННИК** *м. обл.* — салам тутырылган түшәк.

**СОЛО'МЕННЫЙ** — 1. салам ...-ы; *соломенный цвет* — салам төсе; 2. салам(нан ясалган); *соломенная шляпа* — салам эшләпә. ◇ **Соломенные ноги или ножки** *разг. фам. шутл.* — салам сыйрак (нечкә һәм хәлсез аяклар турында әйтелә). **Соломенный вдовец** — хатыныннан вакытлыча читтә булган ир. **Соломенная вдова** — ирennән вакытлыча читтә булган хатын.

**СОЛО'МИНА** *ж.* — 1. бер бөртек салам; 2. сабак (кыяклы ашлыкларның).

**СОЛОМИ'Т** *м. мн.* нет, *тех.* — соломит, саламнан ясалган щит (торак йортларның стеналарын җылытуда кулланыла).

**СОЛО'МКА** *ж.* — 1. *только ед. разг.* к. солома; 2. вак салам; йомшак салам; 3. *только ед. собир. спец.* агач йомычкасы (упаковкага китә торган); 4. соломка (а. *тех.* шырпы ясый торган юка агач; б. *только ед. спец.* конфетның бер төре; в. *только ед. спец.* печеньеның бер төре).

**СОЛОМОКРУ'ТКА** *ж. тех.* — салам ишкеч (машина).

**СОЛОМОПОДАВА'ТЕЛЬ** *м. с.-х.* — салам биргеч (ашлык сугу машинасында махсус җайланма).

**СОЛОМОПОДЪЁМНИК** *м. с.-х.* — салам күтәргеч, салам өйгеч (ашлык сугу машинасында махсус җайланма).

**СОЛОМОРЕ'ЗКА** *ж. с.-х. тех.* — салам кискеч, салам турагыч, салам турау машинасы.

**СОЛОМОТРЯ'С** *м. с.-х.* — салам аергыч (ашлык сугу машинасының саламны орлыктан һәм кибәктән аерып ала торган өлеше).

**СОЛОНЕ'Ц** *м.* — 1. *обл.* к. солончак; 2. *обл.* тозлы күл.

**СОЛОНИ'НА** *ж. мн.* нет — тозлы сыер ите.

**СОЛОНИ'ННЫЙ** — тозлы сыер итеннән (ите салып) пешерелгән.

**СОЛО'НКА** *ж.* — тоз савыты.

**СО'ЛОНО** *разг. нареч.* — тозлап, тозлы; *щи приготовлены слишком солоно* — щи бик тозлы пешерелгән. ◇ **Солоно выразиться** — оятсыз сүз әйтү; тозлап-борычлап әйтү. **Во рту солоно** — авызымда тоз тәме бар. **Не солоно хлебавши** *перен. разг.* — коры кул белән, буш кул белән, коры; *вернулись не солоно хлебавши* — буш кул белән кайттылар. **Солоно пришлось** *разг.* — 1. *безл.* кыенлыклар күрергә туры килде, авырга төште, кыенга төште; 2. күңелгә охшамады.

**СОЛОНОВА'ТЫЙ** *разг.* — тозлырак.

**СОЛОНЦО'ВЫЙ** — к. солончаковый.

**СОЛОНЧА'К** *м.* — тозлак, тозлы туфрак.

**СОЛОНЧАКО'ВЫЙ** — 1. тозлы; *солончаковые почвы* — тозлы туфраклар; 2. тозлы туфракларда үсә торган, тозлакта үсә торган; *солончаковые растения* — тозлы туфракларда үсә торган үсемлекләр.

**СОЛО'НЫЙ** — к. солёный 1.

**СОЛО'ЩИЙ** *обл.* — күп ашаучан, тәмлене яратучан.

**СОЛЬ** I *ж.*—1. тоз; *положить соли в суп* — ашка тоз салу; 2. *только ед. перен. разг.* мәгънә, кызык, тоз, тәм; *в том и состоит вся соль рассказа* — хикәянең бөтен кызыгы да нәкъ шунда; 3. *только ед. перен. устар.* үткер сүз. ◇ **Аттическая соль** *книж.*— үткен тапкыр сүзләр. **Соль земли** *ритор.*— дөнья тоткасы, дөнья терәге (берәр халыкның төп иҗади көчләре, күренекле алдынгы кешеләре турында әйтелә).

**СОЛЬ** II *ср. нескл. муз.*— соль (музыкаль гамманың бишенче нотасы).

**СОЛЬ** III *ж зо л.*— соль (диңгездә яши торган киң, яссы балык).

**СО'ЛЬНЫЙ** *муз. театр.*— ялгыз башкарыла торган.

**СОЛЬФЕ'ДЖИО** *ср. нескл.*— сольфеджио (вокаль күнекмә).

**СОЛЯ'НКА** *ж.*— 1. *бот.* тозлакта үсә торган үсемлек, тозлы туфракларда үсә торган үлән; 2. *разг.* к. селянка.

**СОЛЯНО'Й** —1. тоз ...-ы; *соляная кислота* — тоз кислотасы; 2. тоз чыгару...-ы; *соляные разработки* — тоз чыгару урыны.

**СОЛЯРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— 1. кояш нурлары белән дәвалану; 2. соляризация (фотография пластинкасын кирәгеннән артык тотып каралу дәрәҗәсен киметү).

**СОЛЯ'РИЙ, СОЛЯ'РИУМ** *м. спец.*— солярий (кояш нурлары белән дәвалану өчен җайлаштырылган мәйданчык).

**СОЛЯ'РОВЫЙ** *тех.*— соляр... (нефть куганда барлыкка килгән); *соляровые масла* — соляр майлар.

**СОМ** *м.*— җәен (балык).

**СОМАТИ'ЧЕСКИЙ** *науч.*— тән ...-ы; *соматические болезни* — тән авырулары.

**СОМЁНОК** (*мн.* сомята) *м. разг.*— кечкенә җәен, яшь җәен.

**СО'МКНУТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— тоташлык.

**СО'МКНУТЫЙ** —1. йомылган, йомык; *сомкнутые глаза* — йомык күзләр; 2. тоташ, тоташкан; *сомкнутая колонна* — тоташ колонна.

**СОМКНУ'ТЬ** *сов.*—1. тыгызландыру, тоташтыру; *сомкнуть ряды* — сафларны тоташтыру; 2. *книж.* йому; *сомкнуть очи* — күзләрне йому.

**СОМКНУ'ТЬСЯ** *сов.*—1. тыгызлану, тоташу; 2. *книж. (о глазах)* йомылу.

**СОМНА'МБУЛ** *м.*, **СОМНА'МБУЛА** *ж. мед.*— сомнамбулизм белән авыручы.

**СОМНАМБУЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *мед.*— сомнамбулизм (психик авыру: йокы аралаш үзен-үзе белмичә йөрү һәм аңсыз рәвештә төрле эшләр эшләү).

**СОМНЕВА'ТЬСЯ** *несов.*— шөбһәләнү, шикләнү, шик тоту, икеләнү, ышанып җитмәү.

**СОМНЕ'НИЕ** *ср.*— шик, шөбһә; шикләнү, икеләнү, ышанып җитмәү. ◇ **Без (всякого) сомнения** или **вне (всякого) сомнения** — һичшиксез.

**СОМНИ'ТЕЛЬНО** *в знач. сказ.*— шикле, икеле, шөбһәле; шикләнә(м, сең); *мне сомнительно* — мин шикләнәм; *сомнительно, будет ли это так* — моның шулай булуы икеле.

**СОМНИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — шиклелек, шөбһәлелек.

**СОМНИ'ТЕЛЬНЫЙ** —1. шикле; *сомнительное дело* — шикле эш; 2. шөбһәле; *сомнительная теория* — шөбһәле теория; 3. *книж.* ике төрле аңлашыла торган; *сомнительный комплимент* — ике төрле аңлашыла торган комплимент.

**СОМНО'ЖИТЕЛЬ** *м. мат.*— тапкырлашучы.

**СОМО'ВИЙ** — җәен балыгы ...-ы; *сомовья уха* — җәен (балыгы) шулпасы.

**СОМО'ВИНА** *ж. мн.* нет — җәен (балыгы) ите.

**СОМО'Н** *неизмен. прил.*— алсу сары (төс); *шарф сомон* — алсу сары шарф.

**СОМЧА'ТЬ** *сов. разг.*— чаптырып илтү, очыртып илтү, очыртып илтеп ташлау, бик тиз илтеп ташлау.

**СОН** *м.*—1. *только ед.* йокы; *глубокий сон* — тирән йокы; 2. *перен.* тынлык, йокы (табигатьтә); 3. төш; *видеть сон* — төш күрү; 4. хыял, төш; *всё это сон* — моның барысы да хыял гына (төш кенә). ◇ **Заснуть (спать) вечным сном** или **погрузиться в вечный сон** *ритор.*— мәңге йокыга китү, үлү. **Как во сне** — төштәге кебек, төш кебек. **Ни сном, ни духом (не виноват)** *разг.*— һич тә, һичбер (гаебем юк). **Сквозь сон** — йокы аралаш, йокы арасында. **Сна ни в одном (или ни в едином) глазу** — һичбер йокы керми, бер дә йоклыйсы(м,ң) килми. **Что сей сон значит?** (означает и т. п.) *шутл.*— бу ни дигән сүз? Моны ничек аңларга кирәк?

**СОНАНИМА'ТЕЛЬ** *м. право* — бергә яллаучы; бергә файдалануга алучы.

**СОНАСЛЕ'ДНИК** *м.*, **СОНАСЛЕ'ДНИЦА** *ж. право* — варисташ, бергә варис булып калган кеше.

**СОНАСЛЕ'ДОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— варисташ булу, бергә варис булу, бергә варис булып калу.

**СОНА'ТА** *ж. муз.*— соната (өч-дүрт бүлектән торган музыкаль әсәр).

**СОНАТИ'НА** *ж. муз.*— сонатина (катлаулы булмаган кыска соната).

**СОНЕ'Т** *м. лит.*— сонет (ундүрт юллы шигырь).

**СОНЕ'ТКА** *ж. устар.*— сонетка (электә байлар өендә шалтыратып асрауларны чакыра торган кечкенә кыңгырау).

**СОНЕ'ТНЫЙ** *лит.*— сонет ...-ы; *сонетная композиция* — сонет композициясе.

**СОНЛИ'ВЕЦ** *м.*, **СОНЛИ'ВИЦА** *ж.*— йокычан кеше, йокларга яратучан кеше, йокы капчыгы, йокы чүлмәге, йокыдан баш күтәрмәүчән кеше.

**СОНЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — йокычанлык, йоклыйсы килү, йокы басу, йоклыйсы килеп тору.

**СОНЛИ'ВЫЙ** — йокычан, йокларга яратучан.

**СОНМ** *м. книж. устар.*, *теперь чаще шутл.*—1. чиктән тыш күп, хисапсыз күп, көтү-көтү, бер көтү; *целые сонмы мух* —

көтү-көтү чебен, хисапсыз күп чебен; 2. төркем; *причислить к сонму ... — ...* төркеменә кертү.

**СО'НМИЩЕ** *ср. книж. устар., теперь пренебр.* — к. сонм.

**СО'ННИК** *м. устар.* — төш тәгъбире, тәгъбирнамә, төш юрау китабы.

**СО'ННЫЙ** — 1. йоклаган; *в сонном состоянии* — йоклаган хәлдә; 2. йокылы, йокы баскан; *сонные глаза* — йокылы күзләр; 3. йокыдагы; 4. йоклыйсы килүдән булган; йоклыйсы килеп торган, йокымсыраган; *сонное состояние* — йоклыйсы килеп торган хәл; 5. *перен. неодобр.* сүлпән, хәрәкәтсез, йокыга чумган; *сонная жизнь* — хәрәкәтсез тормыш; 6. йоклату...-ы; йоклата торган; *сонные капли* — йоклата торган тамчылар (дару); 7. йокыга чумган, тын; *сонный лес пусть проснётся, нарядится* (Полонский) — йокыга чумган урман уянсын, бизәнсен; 8. *спец. (о рыбе)* үлгән.

**СОНО'РНЫЙ** *лингв.* — сонор; *сонорные звуки* — сонор авазлар (мәсәлән, р, л, м, н).

**СО'НЯ** *м.* и *ж.* — йокы капчыгы, йокы чүлмәге, йокычан, йокларга яратучан.

**СООБРАЖА'ТЬ** *несов.* — 1. *устар.* к. сообразить 1, 2; 2. *простореч. фам.* баш эшләү, фикер йөртә белү, аңлы булу; *парень дельный, соображает* — егет эшлекле, фикер йөртә белә.

**СООБРАЖА'ТЬСЯ** *несов. устар.* — 1. к. сообразиться; 2. *страд.* һәрьяклап уйланылу, җентекләп уйланылу, һәрьяклап уйлап бәя бирелү.

**СООБРАЖЕ'НИЕ** *ср. книж.* — 1. *только ед. устар.* к. соображать; 2. *только ед.* фикер йөртә белү, уйлау, аңлау; *поступать без соображения* — уйламыйча эш итү; *он лишён всякого соображения* — ул бөтенләй фикер йөртә белми; 3. фикер, уй; *у меня есть свои соображения на этот счёт* — бу турыда минем үз фикерем бар. ◇ **В соображении** *устар.* — уйлап чагыштырганнан соң. **По соображению** *канц. разг.* — тикшереп, уйлап, җентекләп карап. **Принять в соображение** *книж.* — исәпкә алу, искә алу, игътибарга алу.

**СООБРАЗИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — зирәклек, үткен зиһенлелек, тиз төшенүчән булу, тиз аңлаучан булу, тиз тотып алучанлык.

**СООБРАЗИ'ТЕЛЬНЫЙ** — зирәк, үткен зиһенле, тиз төшенүчән, тиз аңлаучан, тиз тотып алучан.

**СООБРАЗИ'ТЬ** *сов.* — 1. *устар.* һәрьяклап уйлап карау, җентекләп уйлау; *сообразить все обстоятельства* — барлык шартларны (хәлләрне) җентекләп уйлау; 2. аңлау, төшенү, аңлап алу, төшенеп алу; *он сразу сообразил, что это будет очень выгодно* — бу аның өчен файдалы икәнлеген ул шунда ук аңлап алды.

**СООБРАЗИ'ТЬСЯ** *сов. устар.* — к. сообразоваться.

**СООБРА'ЗНО** *нареч.* — буенча, ...-га туры китереп, ...-га ярашлы рәвештә; *поступать сообразно с законом* — закон буенча эш итү.

**СООБРА'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — туры килү(чәнлек), ярашлылык.

**СООБРА'ЗНЫЙ** *книж.* — туры килә торган, ярашлы (булган).

**СООБРАЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — яраштыру, туры китерү, туры китереп эшләү.

**СООБРАЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. книж.* — ...-ны истә тотып эш итү, ...-дан чыгып эш итү, исәпләшү, санашу; *сообразоваться со своими возможностями* — үзеңнең мөмкинлекләреңнән чыгып эш итү.

**СООБРАЗО'ВЫВАТЬ** *несов. книж.* — к. сообразовать.

**СООБРАЗО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. сообразоваться; 2. *страд.* яраштырылу, туры китерелү.

**СООБЩА'** *нареч.* — күмәкләп, бергә, бергәләшеп.

**СООБЩА'ТЬ** *несов.* — к. сообщить.

**СООБЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *книж.* к. сообщиться; 2. тоташу; *Москва-река сообщается с Волгой* — Москва елгасы Идел белән тоташа; 3. аралашу, хәбәрләшү, бәйләнеш тоту; *они сообщаются друг с другом письмами* — алар үзара хатлар белән хәбәрләшәләр; 4. *страд.* хәбәр ителү, белдерелү, игълан ителү; 5. *страд.* бирелү.

**СООБЩЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. (действие)* к. сообщить; 2. хәбәр, белдерү, белдермә; *по последним сообщениям* — соңгы хәбәрләр буенча; 3. бәйләнеш, элемтә. ◇ **Пути сообщения** — аралашу юллары (тимер юллар, су юллары).

**СОО'БЩЕСТВО** *ср.* — 1. *книж.* төркем, берләшмә; *преступное сообщество* — җинаятьчеләр төркеме; 2. *биол.* бергәлек; *сообщество растительное* — үсемлекләр бергәлеге.

**СООБЩИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — уртаклашучанлык, аралашучанлык.

**СООБЩИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — уртаклашучан; аралашучан; эчкерсез.

**СООБЩИ'ТЬ** *сов.* — 1. хәбәр итү; хәбәр бирү, белдерү; *сообщить радостную весть по телеграфу* — телеграф аша шатлыклы хәбәр белдерү; *сообщить о чём-н. по радио* — берәр нәрсә турында радиодан хәбәр итү; 2. *книж.* йоктыру; *больной сообщил свою болезнь окружающим* — авыру кеше үзенең авыруын тирә-ягындагыларга йоктырган. ◇ **Отец сообщил сыну интерес к наукам** — фән белән кызыксыну әтисеннән улына күчкән. **Сообщить железу магнитные свойства** — тимерне магнитландыру. **Сообщить водонепроницаемость ткани** — тукыманы су үткәрми торган итеп ясау (су үткәрми торган хәлгә китерү).

**СООБЩИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — күчү; йогу.

**СОО'БЩНИК** *м.*, **СОО'БЩНИЦА** *ж. офиц.* — (җинаятьтә, җинаять эшендә) катнашучы, иярчен, бергә җинаять эшләүче.

**СОО'БЩНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *офиц.* — катнашу (җинаять эшендә яки шундый эшне хәзерләүдә).

**СООПЕКУ'Н** *м. офиц. право* — опекундаш, бергә опекунлык итүче кеше.

**СООРУДИ'ТЬ** *сов.*— 1. *книж.* төзү, салу, кору, торгызу, күтәрү; *соорудить здание*— бина салу; 2. *разг. ирон.* уйлап чыгару; *кляузу, чай, какую-нибудь соорудил* (С.-Щедрин) — нинди дә булса яла уйлап чыгаргандыр инде; 3. *просторен. фам. шутл. (устроить)* оештыру; (*приготовить*) әзерләү, пешерү.

**СООРУЖА'ТЬ** *несов.*— к. соорудить.

**СООРУЖА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— төзелү, корылу, салыну.

**СООРУЖЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед. (действие)* к. соорудить; 2. бина, корылма; *монументальное сооружение* — монументаль корылма.

**СООТВЕ'ТСТВЕННО** *нареч.* — 1. *канц.* шуңа ярашлы рәвештә, тиешенчә; *когда получу инструкцию, тогда соответственно и поступлю* — инструкция алгач, тиешенчә эш итәрмен; 2. *в знач. предлога с дат. п. книж.* ...-га нигезләнеп, ... ярашлы рәвештә, ...-га таянып, карап, буенча, туры китереп; *поступать соответственно своим убеждениям* — үз карашларыңа (үз фикерләреңә) таянып эш итү; 3. *в знач. союза офиц. канц.* шулай ук, шуның белән бергә; *фруктовые деревья, соответственно и прочие культурные растения, требуют ухода* — җимеш агачларына, шулай ук игеп үстерелә торган башка үсемлекләргә дә, тәрбия кирәк.

**СООТВЕ'ТСТВЕННЫЙ** *книж. устар.*— к. соответствующий.

**СООТВЕ'ТСТВИЕ** *ср.*—1. туры килү, ярашу; 2. *мат.* тиңдәшлек.

**СООТВЕ'ТСТВОВАТЬ** *несов.*—туры килү, ярашу, туры килеп тору.

**СООТВЕ'ТСТВУЮЩИЙ** — 1. туры килә торган; 2. яраклы; *необходимо найти соответствующее помещение* — яраклы бина табарга кирәк; 3. тиешле, тиешле булган; *обратиться к инспектору соответствующего района* — тиешле районның инспекторына мөрәҗәгать итү. ◇ **Поступить соответствующим образом** — тиешенчә эш итү.

**СООТВЕ'ТЧИК** *м.*, **СООТВЕ'ТЧИЦА** *ж. офиц. право* — җавапташ, бергәләп җавап бирүче.

**СООТЕ'ЧЕСТВЕННИК** *м.*, **СООТЕ'ЧЕСТВЕННИЦА** *ж. книж.*—ватандаш, илдәш.

**СООТНЕСТИ'** *сов. книж.*— үзара бәйләнешен билгеләү, үзара мөнәсәбәтен билгеләү.

**СООТНОСИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— үзара бәйләнешлелек, үзара бәйләнештә булу, үзара мөнәсәбәттә булу.

**СООТНОСИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — үзара бәйләнешле, үзара бәйләнештә булган, үзара мөнәсәбәттә булган.

**СООТНОСИ'ТЬ** *несов. книж.*— к. соотнести.

**СООТНОСИ'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. үзара бәйләнешле булу, үзара бәйләнештә булу, үзара мөнәсәбәттә булу; 2. *страд.* (үзара) бәйләнеше билгеләнү, мөнәсәбәте билгеләнү.

**СООТНОШЕ'НИЕ** *ср. книж.*— үзара бәйләнеш, үзара мөнәсәбәт.

**СОО'ТЧИЧ** *м. устар.*— к. соотечественник.

**СОПА'ТКА** *ж. обл. вульг.*—танау, борын.

**СОПА'ТЫЙ** *обл.*— мышнаучан.

**СОПЕ'ЛКА** *ж. обл.*— сыбызгы, сорнай.

**СОПЕ'ЛЬ** *ж.*— 1. *обл.* к. сопелка; 2. *спец.* һава өрдергеч көпшә, һава өрдергеч труб- ка (мәсәлән, тимерче учагы белән күрекне тоташтыра торган көпшә).

**СОПЕ'ЛЬЩИК** *м. обл.* — сыбызгы сызгыртучы, сорнайда уйнаучы.

**СОПЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *(действие)* к. сопеть 1; 2. мышнаган тавыш; *послышалось сопение* — мышнаган тавыш ишетелде.

**СОПЕРЕЖИВА'ТЬ** *несов. книж.*— (кайгы-хәсрәтне) уртаклашу, бергә кичерү.

**СОПЕ'РНИК** *м.*, **СОПЕ'РНИЦА** *ж.* — 1. ярышучы; *достойный соперник* — лаеклы ярышучы; 2. көндәш; *счастливый соперник* — бәхетле көндәш; 3. тиңдәш.

**СОПЕ'РНИЧАТЬ** *несов.*— 1. ярышу; узышу, (бер-берсен) узарга тырышу, (бер-берсеннән) уздырырга тырышу; 2. *перен.* тиң булу, тигез булу; ярышу; *сибирские реки соперничают по длине с реками Южной Америки* — Себер елгалары үзләренең озынлыгы ягыннан Көньяк Америка елгаларына тиңнәр.

**СОПЕ'РНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — 1. көндәшлек; *соперничество в любви* — мәхәббәттә көндәшлек; 2. ярышу, бер-берсен узарга тырышу; бер-берсеннән уздырырга тырышу; *соперничество империалистических держав в гонке вооружений*— империалистик державаларның ашкынып коралланууда бер-берсеннән уздырырга тырышуы.

**СОПЕ'ТЬ** *несов.*— 1. мышнау; 2. *обл. старин.* сыбызгы сызгырту, сорнайда уйнау.

**СО'ПКА** *ж.*— сопка (1. кечкенә тау; 2. Ерак Көнчыгышта, мәсәлән, Камчаткада янар тау).

**СОПЛЕМЕ'ННИК** *м.*, **СОПЛЕМЕ'ННИЦА** *ж. книж. устар.*— кабиләдәш.

**СОПЛЕМЕ'ННЫЙ** *книж. устар.* — бер кабилә...-ы, кабиләдәш....; *соплеменные народы* — кабиләдәш халыклар.

**СО'ПЛИ** *мн.* (*ед.* сопля) *просторен.*— 1. маңка; 2. *только ед. перен. презрит.* маңка, булдыксыз, җебегән (кеше). ◇ **Соплей перешибёшь** *просторен. вульг.*—төртсәң егылырга тора, бүрек бәреп егарсың, чиртсәң үләргә тора (хәлсез кеше турында).

**СОПЛИ'ВЕЦ** *м.*, **СОПЛИ'ВИЦА** *ж. просторен.*— 1. маңкалы кеше; 2. *пренебр.* маңка, маңка малай; 3. *бран. презрит.* к. сопляк 3.

**СОПЛИ'ВОСТЬ** *ж. разг.*— маңкалылык.

**СОПЛИ'ВЫЙ** *просторен.*— 1. маңкалы; *сопливый ребёнок* — маңкалы бала; 2. *пренебр.* маңка ... (әле яшь һәм тәҗрибәсез); *сопливый мальчишка* — маңка малай.

**СОПЛЯ'К** *м. просторен.*— 1. *неодобр.* маңкалы бала; 2. *пренебр.* маңка, маңка малай; 3. *презрит.* маңка тавык.

**СОПОДЧИНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. соподчинить.

**СОПОДЧИНЁННЫЙ** — 1. *книж.* (бер үк

вакытта бер үк нәрсәгә) буйсындырылган; 2. *грам.* тиңдәш иярчен; *соподчинённые предложения* — тиңдәш иярчен җөмләләр.

**СОПОДЧИНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *грам.*— тиңдәш иярту ...-ы; *соподчинительная конструкция* — тиңдәш иярту конструкциясе.

**СОПОДЧИНИ'ТЬ** *сов.*— 1. *книж.* (бер үк вакытта бер үк нәрсәгә) буйсындыру; *соподчинить все районы центру* — барлык районнарны бер үзәккә буйсындыру; 2. *грам.* тиңдәш иярту (җөмләләрне).

**СОПОДЧИНЯ'ТЬ** *несов.книж. грам.*— к. соподчинить.

**СОПОДЧИНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. *книж.* (бер үк вакытта бер үк нәрсәгә) буйсындырылу; 2. *грам.* тиңдәш ияртелү.

**СОПОСТАВИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— чагыштырыла алырлык булу, чагыштырырлык булу.

**СОПОСТАВИ'МЫЙ** *книж.*— чагыштырыла алырлык, чагыштырма..., чагыштырырлык.

**СОПОСТА'ВИТЬ** *сов. книж.* — чагыштыру.

**СОПОСТАВЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. сопоставить.

**СОПОСТАВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— чагыштырылу.

**СОПОСТАНО'ВЩИК** *м. театр. кино* — (спектакль, картинаны) бергәләп куючы.

**СОПРА'ННЫЙ** *муз.*— сопрано ...-ы; *сопранная партия* — сопрано партиясе.

**СОПРА'НО** *ср. нескл. муз.* — сопрано (1. җырчы хатын-кызларда иң югары, нечкә тавыш; 2. шундый тавышлы җырчы хатын-кыз).

**СОПРА'НОВЫЙ** *муз.*— к. сопранный.

**СОПРЕДЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— чиктәшлек, чикләре бергә туры килү, янәшәлек.

**СОПРЕДЕ'ЛЬНЫЙ** *книж.*— чиктәш, чикләре бергә туры килә торган, янәшә.

**СОПРЕ'ТЬ** *сов.*— кызып яну, кызып черү, кызып череп бетү.

**СОПРИКАСА'ТЬСЯ** *несов. книж.*—1. чиктәш булу, янәшә булу, барып тоташу; *пчельник совхоза соприкасается с лесом соседнего колхоза* — совхозның умарталыгы күрше колхозның урманы белән янәшә, совхозның умарталыгы күрше колхозның урманына барып тоташа; 2. *перен.* (үзара) бәйләнештә булу, ...арасында бәйләнеш булу, уртаклык булу; *наши интересы ни в чём не соприкасаются* — безнең интереслар арасында һичбер нинди бәйләнеш юк; 3. (бер-беренә) тию, тиеп тору, орыну; бәрелеп тору; *концы провода соприкасаются* — тимер чыбыкның очлары бер-беренә тиеп торалар; 4. *перен.* аралашу, катнашу, танышу, очрашу; *приходится соприкасаться с различными людьми* — төрле кешеләр белән аралашырга туры килә.

**СОПРИКОСНОВЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. к. соприкасаться 1, 4; 2. очрашу; *главные силы вошли в соприкосновение с противником* — төп көчләр дошман белән очраштылар. ◇ **У нас с ним нет никаких точек соприкосновения** — безнең аның белән һичбер уртак нәрсәбез юк.

**СОПРИКОСНОВЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.*— 1. чиктәшлек, янәшәлек; 2. аралашканлык, катнашканлык, аралашу, катнашу.

**СОПРИКОСНУ'ТЬСЯ** *сов. однокр. книж.*— 1. тию, тиеп китү, орыну, орынып китү, бәрелеп китү; 2. к. соприкасаться 4.

**СОПРИЧА'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.*— 1. катнашы булу, катнашканлык; 2. бергәләшеп катнашу, бергәләшеп эшләү.

**СОПРИЧА'СТНЫЙ** *книж. устар.*—1. катнашы булган; катнашкан; 2. бергәләп катнашкан, бергәләшеп эшләгән.

**СОПРИЧЕ'СТЬ** *сов. устар.*— к. сопричислить.

**СОПРИЧИ'СЛИТЬ** *сов. книж. устар.*— бер рәткә кую, ... рәтенә кертү; *сопричислить кого-нибудь к числу лучших писателей* — берәр кешене иң яхшы язучылар рәтенә кертү.

**СОПРИЧИСЛЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. сопричислить.

**СОПРИЧИСЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.*— бер рәткә куелу, ... рәтенә кертелү.

**СОПРИЧИТА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— к. сопричесть.

**СОПРИЧИТА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.*— к. сопричисляться.

**СОПРОВОДИ'ТЕЛЬ** *м. офиц.*— озатучы, озата баручы.

**СОПРОВОДИ'ТЕЛЬНЫЙ** *офиц.* — бергә җибәрелә торган; *сопроводительный бланк к посылке* — посылка белән бергә җибәрелә торган бланк.

**СОПРОВОДИ'ТЬ** *сов. книж.*— к. сопровождать 4, 5, 6.

**СОПРОВОЖДА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. *офиц.* озату, озата бару; *командующего сопровождали адъютанты* — командующийны адъютантлар озата бара иде; 2. *перен.* ... белән үтү, ...-лы үтү; *успех сопровождает его концерты* — аның концертлары уңышлы үтә; 3. юл буе булу; *буря сопровождала наш корабль* — без корабльдә барганда юл буе давыл булды; 4. *перен.* (бер үк вакытта) булу, кушылып уйнау, кушылып җырлау; *музыку сопровождало пение* — музыкага кушылып җырладылар; .5 *канц.* бергә җибәрү, теркәп җибәрү; *заявление необходимо сопровождать соответствующими документами* — гаризага тиешле документларны теркәп җибәрергә кирәк; 6. *перен.* ныгыту, раслау; *все свои утверждения автор сопровождает обильными выписками из первоисточников* — автор үзенең барлык фикерләрен беренче чыганаклардан күп санда алынган өземтәләр белән раслый.

**СОПРОВОЖДА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. *страд.* озатылу; 2. (бергә, бер үк вакытта, бер рәттән) булу; *дождь сопровождался грозой* — яңгыр яуганда күк күкрәп яшен яшьнәде (күк күкрәп, яшен яшьнәп яңгыр яуды); 3. *перен.* сәбәп булу, ... нә-

тиҗәсендә килеп чыгу; *болезнь сопровождалась осложнениями* — авыру нәтиҗәсендә икенче бер авырулар килеп чыкты.

**СОПРОВОЖДЕ'НИЕ** *ср. мн* нет, *книж.*— 1. к. сопроводить; 2. нәрчен күренеш, нәрчен процесс; 2. *муз.* аккомпанемент; *музыкальное сопровождение* — музыкаль аккомпанемент. ◇ **В сопровождении** *книж.*— 1. ... белән бергә; *в сопровождении друзей* — дуслары белән бергә; 2. ...-га кушылып; *петь в сопровождении рояля* — роядьгә кушылып җырлау.

**СОПРОТИВЛЕ'НЕЦ** *м. неодобр.* — нык каршы торучы.

**СОПРОТИВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— 1. *(действие)* к. сопротивляться; 2. *физ.* каршылык; *сопротивление материалов* — материаллар каршылыгы.

**СОПРОТИВЛЯ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— каршы тору сәләте, каршылык күрсәтү сәләте, каршы тора алу(чанлык).

**СОПРОТИВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— каршы тору, каршылык күрсәтү; карышу.

**СОПРЯГА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— бергә кушу, берләштерү.

**СОПРЯГА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. устар.*— кушылу, берләштерелү.

**СОПРЯЖЁННЫЙ** *книж.*— 1. *устар.* кушылган, берләштерелгән; 2. бәйләнгән; *это сопряжено с большими трудностями* — бу зур кыенлыкларга бәйләнгән; 3. нярмә (бер-берсенә бәйләнгән); *сопряжённые точки* — нярмә нокталар.

**СОПРЯ'ЧЬ** *сов. книж. устар.*— к. сопрягать.

**СОПУ'Н** *м.*, **СОПУ'НЬЯ** *ж. простореч. фам.*— мышнаучы, мышнавык.

**СОПУ'ТНИК** *м. книж. поэт. устар.*— к. спутник.

**СОПУ'ТСТВОВАТЬ** *несов. книж.* — 1. озату, озата бару; юлдаш булу, бергә бару (йөрү); *сопутствовать в прогулке* — прогулкада юлдаш булу; 2. (бер үк вакытта, беррәттән, бергә) булу, ...-ганда булу; *многим болезням сопутствует сильный жар* — күп кенә авырулар вакытында температура югары була.

**СОПУ'ТСТВУЮЩИЙ** *книж.*— 1. юлдаш булучы, бергә баручы (йөрүче); 2. өстәмә..., нярчен...; *сопутствующие обстоятельства* — нярчен шартлар.

**СОР** *м. мн.* нет — 1. чүп; 2. *перен.* чүп-чар; *в его сочинениях много сору* — аның әсәрләрендә чүп-чар бик күп. ◇ **Выносить сор из избы** *разг.*— өендәге тышка чыгару, өендәге чүпне тышка чыгару.

**СОРАЗМЕ'РИТЬ** *сов. книж.* — тигезләү, яраштыру, туры китерү.

**СОРАЗМЕ'РНО** *нареч.*— ...-га күрә, ...-га карап; *тратить деньги соразмерно заработку* — акчаны эш хакына карап тоту.

**СОРАЗМЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— туры килгәнлек, туры килеп тору (үлчәү, күләм яки микъдар ягыннан).

**СОРАЗМЕ'РНЫЙ** *книж.*— туры килә торган, туры килеп тора торган (үлчәү, күләм яки микъдар ягыннан).

**СОРАЗМЕРЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. соразмерить.

**СОРАЗМЕРЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. *страд.* тигезләнү, яраштырылу, туры китерелү; 2. туры килү, туры килеп тору (үлчәү, күләм яки микъдар ягыннан).

**СОРА'ТНИК** *м. книж.*, **СОРА'ТНИЦА** *ж. книж. ритор.*— көрәштәш.

**СОРВАНЕ'Ц** *м. разг.*— шук, шаян, чая.

**СОРВА'ТЬ** I *сов.*— 1. өзү, өзеп алу; *сорвать цветок* — чәчәк өзү; 2. тартып алу; *сорвать шляпу с кого-н.*— (берәр кешенең) эшләпәсен (башыннан) тартып алу; 3. куптарып алып ташлау; куптарып алып китү; *бурей сорвало крышу* — җил-давыл өй түбәсен куптарып алып ташлаган; 4. *разг. фам.* ...-га мәҗбүр итү; *сорвать аплодисменты* — алкышларга мәҗбүр итү (алкышлату); 5. *простореч.* косу; *его сорвало желчью* — үт суын коскан. ◇ **Сорвать зло** (гнев, злобу, сердце и т. п.) *на ком-чем-н.* и *с кого-чего разг.*— (берәр кешедән яки берәр нәрсәдән) ачу алу, үч алу (эт ачуын беттән алу, торма ачуын тоздан алу). **Сорвать маску** — к. маска. **Сорвать с места** *разг.*— китәргә мәҗбүр итү. **Сорвать с работы** *разг.*— эшен туктату, эшен туктатырга мәҗбүр итү.

**СОРВА'ТЬ** II *сов. разг.*— бозу, юкка чыгару; өзү; *сорвать дело* — эшне бозу; *сорвать заседание* — утырышны өзү.

**СОРВА'ТЬСЯ** I *сов.*— 1. ычкыну, ычкынып китү; *собака сорвалась с цепи* — эт чылбырыннан ычкынган; *как с цепи сорвался* — әйтерсең лә бәйдән ычкынган; баудан ычкынганмыни; *сорвалось замечание* — шелтә ычкынды; 2. ишелеп төшү; егылып төшү; *сорваться со скалы* — кыядан егылып төшү; 3. өзелеп төшү; (ычкынып) төшү; *лампа сорвалась с потолка* — лампа түшәмнән өзелеп төште. ◇ **Сорваться с места** *разг. фам.*— кинәт атылып тору, кинәт атылып торып йөгереп китү.

**СОРВА'ТЬСЯ** II *сов.*, 1 и 2 *л. не употр.*, *разг.*— бозылу, юкка чыгу, (эш) барып чыкмау, (эш) уңмау; *дело сорвалось!* — эш барып чыкмады!

**СОРВИГОЛОВА'** *м. разг.* — чая, чая кеше; башкисәр.

**СОРГАНИЗОВА'ТЬ** *сов.* — оештыру.

**СОРГАНИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* — оешу, берләшү.

**СОРГАНИЗО'ВЫВАТЬ** *несов.* — к. сорганизовать.

**СОРГАНИЗО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. сорганизоваться; 2. *страд.* оештырылу, берләштерелү.

**СО'РГО** *ср. нескл.* — сорго (тарыга охшаш игүле үсемлек).

**СОРДИ'НА** *ж. муз. устар.* — к. сурдина.

**СОРЕВНОВА'НИЕ** *ср.* — ярыш; *социалистическое соревнование* — социалистик ярыш.

**СОРЕВНОВА'ТЕЛЬ** *м. книж. устар.* — ярышучы. ◇ **Член соревнователь** *офиц. дореволю.*—ярышучы әгъза (берәр төрле җәмгыятьнең хокукы тулы булмаган члены).

**СОРЕВНОВА'ТЬ** *несов. книж. устар.* —

уздырырга тырышу, ярышып узарга тырышу.

**СОРЕВНОВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. ярышу; 2. к. соревновать.

**СОРЕЖИССЁР** *м. театр. кино* — бергә режиссёрлык итүче кеше, режиссёрдаш.

**СОРИ'НКА** *ж.* — чүп, чүп бөртеге; *в глаз попала соринка* — күземә чүп кергән.

**СОРИ'ТЬ** *несов.* — 1. чүпләү; *не сорите в комнате* — бүлмәдә чүпләмәгез; 2. *перен. разг.* туздыру, җилгә очыру, әрәм-шәрәм итү; бушка (әрәмгә) түгү; *сорить деньгами* — акча туздыру.

**СО'РНЫЙ** — 1. чүп ...-ы; *сорная куча* — чүп өеме; 2. чүп...; *сорная трава* — чүп үлән.

**СОРНЯ'К** *м.* — чүп үлән.

**СОРО'ДИЧ** *м. устар.* — 1. кардәш, туган; 2. якташ; *сибиряки — мои сородичи* — Себер кешеләре — минем якташларым.

**СО'РОК** — кырык.

**СОРО'КА** I *ж.* — саескан. ◇ **Заладила сорока Якова (одно про всякого)** *разг.* — бер балык башын чәйни.

**СОРО'КА** II *ж. обл. истор.* — сорока (борын заманда хатын-кызлар кия торган баш киеме).

**СОРОКАВЕДЁРНЫЙ** — кырык чиләкле, кырык чиләк сыешлы.

**СОРОКАГРА'ДУСНЫЙ** — кырык градус..., кырык градуслы.

**СОРОКАДНЕ'ВНЫЙ** — кырык көнлек.

**СОРОКАКОПЕ'ЕЧНЫЙ** — кырык тиенлек.

**СОРОКАЛЕ'ТИЕ** *ср.* — 1. кырык ел; *истекшее сорокалетие* — үткән кырык ел; 2. кырык еллык; *сорокалетие общественной деятельности* — иҗтимагый эшчәнлекнең кырык еллыгы.

**СОРОКАЛЕ'ТНИЙ** — 1. кырык ел буена сузылган, кырык елга сузылган; *сорокалетняя дружба* — кырык ел буена сузылган дуслык; 2. кырык яшьлек, кырык яшендәге; *сорокалетний мужчина* — кырык яшьлек ир кеше; 3. кырык еллык; *сорокалетний юбилей* — кырык еллык юбилей.

**СОРОКАМИНУ'ТНЫЙ** — кырык минутлык, кырык минутлы, кырык минутка сузылган.

**СОРОКАПУДО'ВЫЙ** — кырык потлы.

**СОРОКАРУБЛЁВЫЙ** — кырык сумлык.

**СОРОКАЧАСОВО'Й** — кырык сәгатьлек, кырык сәгатьле, кырык сәгатькә сузылган.

**СОРОКОВИ'НЫ** *только мн. обл.* — к. сорочины.

**СОРОКО'ВКА** *ж. простореч. устар.* — чәкүшкә (чиләкнең кырыктан бер өлеше сыешлы шешә).

**СОРОКОВО'Й** — 1. кырыгынчы; 2. *простореч.* к. сорокаведёрный.

**СОРОКОНО'ЖКА** *ж.* — кырыгаяк.

**СОРО'М** *м. мн.* нет, *обл.* — к. срам.

**СОРО'ЧИЙ** — саескан ...-ы; *сорочье яйцо* — саескан йомыркасы.

**СОРОЧИ'НЫ** *только мн. церк. обл.* — кырыгы (үлгәнә кырык көн тулуы).

**СОРО'ЧКА** *ж.* — 1. күлмәк, эчке күлмәк; 2. *спец.* тышлык; 3. *спец.* тышлык материал. ◇ **Родиться в сорочке** *шутл.* — күлмәктән туу, бәхет йөзлеге белән туу.

**СОРТ** *м.* — сорт, төр.

**СОРТА'МЕНТ** *м. простореч. тех.* — к. сортимент.

**СОРТИМЕ'НТ** *м. тех.* — сортимент (1. товарны сортларга аеруда нигез итеп алына торган билгеләр, сыйфатлар; 2. теге яки бу производствода эшләп чыгарыла яки кулланыла торган предметларның барлыгы бергә).

**СОРТИ'Р** *м. простореч. фам.* — бәдрәф.

**СОРТИРОВА'ЛЬНЫЙ** *спец.* — к. сортировочный.

**СОРТИРОВА'ТЬ** *несов.* — сортлау, сортларга аеру.

**СОРТИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — сортлану, сортларга аерылу.

**СОРТИРО'ВКА** *ж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. сортировать; 2. *тех. с.-х.* сортировка, сортлау машинасы; *картофельная сортировка* — бәрәңге сортлау машинасы; 3. *ж.-д.* к. сортировочная.

**СОРТИРО'ВОЧНАЯ** *ж. в знач. сущ. спец.* — сортлау бүлмәсе, сортларга аеру бүлмәсе (магазинда). ◇ **Сортировочная станция** — сортировочный станция (тимер юлда составларны таратып төзи торган пункт).

**СОРТИРО'ВОЧНЫЙ** — сортлау ...-ы; сортларга аера торган; *сортировочная машина* — сортлау машинасы.

**СОРТИРО'ВЩИК** *м.*, **СОРТИРО'ВЩИЦА** *ж.* — 1. сортлаучы, сортларга аеручы; 2. *ж.-д.* сортировочныйда эшләүче эшче.

**СО'РТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — сортлылык.

**СО'РТНЫЙ** *спец.* — югары сортлы, сортлы.

**СОРТОВА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. сортировать.

**СОРТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — к. сортироваться.

**СОРТОВО'Д** *м. с.-х. устар.* — орлыкчылык белгече.

**СОРТОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *с.-х. устар.* — орлыкчылык.

**СОРТОВО'Й** *спец. с.-х.* — сортлы, югары сыйфатлы.

**СОРТОИСПЫТА'НИЕ** *ср. с.-х.* — сортын сынау, орлыкның сортын (сыйфатын) билгеләү.

**СОРТООБНОВЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — сорт яңарту.

**СОРТОПРОКА'ТКА** *ж. мн.* нет, *тех.* — сортлы тимер прокатлау.

**СОРТОПРОКА'ТЧИК** *м. спец.* — сортлы тимер прокатлаучы (эшче).

**СОРТОСМЕ'НА** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — сорт алмаштыру.

**СОСА'ЛЬЦЕ** *ср. биол.* — к. присоска.

**СОСА'ЛЬЩИК** *м. зоол.* — имгеч суалчан.

**СОСА'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — имү ...-ы; имгеч ...; *сосательные движения* — имү хәрәкәтләре.

**СОСА'ТЬ** *несов.* — 1. имү; *сосать молоко* — сөт имү; *сосать палец* — бармак имү; 2. суыру; *сосать сахар* — шикәр

суыру; *сосать деньги* — акча суыру; 3. сыкрау, әрнү, сызлау; *под ложечкой сосёт* — күкрәк авызым әрни; 4. *перен.* әрнетү, яндыру, көйдерү, җәфалау; *тоска сосёт меня* — сагыш яндыра мине. ◇ **Сосать кровь** — кан эчү.

**СОСВА'ТАТЬ** *сов.* — к. сватать 1.

**СОСЕ'Д** *м.*, **СОСЕ'ДКА** *ж.* — 1. күрше; 2. күрше ил.

**СОСЕ'ДИТЬ** *несов.— 1 л. не употр.* күрше булу, күрше булып тору.

**СОСЕ'ДНИЙ** — күрше ...; *соседний дом* — күрше өй.

**СОСЕ'ДСКИЙ** *разг.* — күрше...-ы, күршеләр ...-ы; *соседские дети* — күрше балалары; *соседский дом* — күрше өе.

**СОСЕ'ДСТВЕННЫЙ** *книж. устар.* — к. соседний.

**СОСЕ'ДСТВО** *ср. мн.* нет — 1. күршелек, күрше булу, күрше; *неприятное соседство* — күңелгә ятышсыз күршелек; 2. *собир. устар.* күршеләр, күрше-күлән. ◇ **В соседстве с** *кем-чем* — (берәр кешенең) күршесендә, (берәр нәрсәнең) янында. **По соседству** *с кем* — (берәр кешенең) күршесендәге, күршедәге.

**СО'СЕНКА** и *разг.* **СОСЁНКА** *ж.* — к. сосна. ◇ **С бору да с сосенки** (поговорка) *пренебр.* — төрле җирдән аз-азлап җыелган, аннан-моннан җыелган.

**СОСЕ'Ц** *м. чаще мн. книж.* — к. сосок 1.

**СОСИ'СКА** *ж.* — сосиска (колбасаның бер төре).

**СО'СКА** *ж.* — имезлек.

**СОСКА'БЛИВАТЬ** *несов.*— к. соскоблить.

**СОСКА'БЛИВАТЬСЯ** *несов.* —1. к. соскоблиться; 2. *страд.* кырылу, кырып ташлану, әрчеп алыну, кырып алыну, әрчеп ташлану.

**СОСКА'КИВАТЬ** *несов.* — к. соскочить.

**СОСКА'ЛЬЗЫВАТЬ** *несов.*— к. соскользнуть.

**СОСКОБЛИ'ТЬ** *сов.* — кыру, кырып ташлау, әрчеп алу, кырып алу, әрчеп ташлау.

**СОСКОБЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — кырылу.

**СОСКОВИ'ДНЫЙ** *книж. спец.* — к. сосцевидный.

**СОСКОЛЬЗНУ'ТЬ** *сов.* — 1. шуып төшү; *соскользнуть по шесту на землю* — колга буйлап җиргә шуып төшү; 2. ычкыну, ычкынып китү, төшү; *колёса соскользнули с рельсов* — тәгәрмәчләр рельстан төшкән; 3. *перен. разг.* тайпылу, читкә китү; *соскользнуть с правильного пути* — дөрес юлдан тайпылу.

**СОСКОЧИ'ТЬ** *сов.* — 1. сикереп төшү; *соскочить на землю* — җиргә сикереп төшү; 2. сикереп тору; *соскочить с дивана* — диваннан сикереп тору; 3. ычкыну, ычкынып китү; (ычкынып) төшү; *дверь соскочила с петель* — ишек күгәненнән ычкынган; 4. *перен. разг.* юкка чыгу, бетү, качу; *сонливость сразу соскочила с него* — шунда ук аның йокысы качты.

**СОСКРЕБА'ТЬ** I *сов. простореч. обл.*—к. соскрести.

**СОСКРЕБА'ТЬ** II *несов. простореч.* — к. соскрести.

**СОСКРЁБЫВАТЬ** *несов. разг.* — к. соскрести.

**СОСКРЁБЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. кырып чистартылу, кырып ташлану; 2. көрәлү, көрәп ташлану, көрәп чистартылу.

**СОСКРЕСТИ'** *сов.* — 1. кырып чистарту, кырып ташлау; *соскрести грязь с сапог* — күн итекләргә ябышкан пычракны кырып чистарту; 2. көрәү, көрәп ташлау, көрәп чистарту; *соскрести снег с тротуаров* — тротуарлардан карны көрәп ташлау.

**СОСКУ'ЧИТЬСЯ** *сов.* — 1. эч пошу; *в одиночестве соскучишься* — ялгыз эчең пошар; 2. сагыну, ямансылау; *соскучиться по родным местам* — туган җирләрне сагыну.

**СОСЛАГА'ТЕЛЬНЫЙ: сослагательное наклонение** *грам.* — шарт фигыль төркемчәсе.

**СО'СЛАННЫЙ** — сөргенгә җибәрелгән (кеше).

**СОСЛА'ТЬ** *сов.* — сөрү, сөргенгә җибәрү.

**СОСЛА'ТЬСЯ** *сов.* — сылтау итү, таяну, дәлил итеп китерү.

**СО'СЛЕПА, СО'СЛЕПУ** *нареч. разг.* — сукырлыктан, сукыр булу сәбәпле; сукыр килеш.

**СОСЛО'ВИЕ** *ср. истор. дореволюц. загр.*— катлау, сословие. ◇ **Третье сословие** — к. третий.

**СОСЛО'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет. *истор. дореволюц. загр.* — 1. (теге яки бу) сословиенең кешесе булу, (теге яки бу) катлауның кешесе булу; 2. сословиеләргә (катлауларга) бүленү принцибы.

**СОСЛО'ВНЫЙ** — 1. *дореволюц.* сословие ...-ы, (аерым) катлаулар...-ы, (аерым) сословиеләр ...-ы; *сословные представители* — (аерым) катлаулар вәкилләре; *сословные интересы* — сословие интереслары; 2. катлауларга бүленгән, сословиеләргә бүленгән; *сословное государство* — катлауларга бүленгән дәүләт; 3. катлаулар вәкаләте белән чикләнгән; *сословная монархия* — катлаулар вәкаләте белән чикләнгән монархия; 4. югары катлауларга хас булган; *сословный дух* — югары катлауларга хас булган рух.

**СОСЛУЖИ'ВЕЦ** *м.*, **СОСЛУЖИ'ВИЦА** *ж.* — хезмәттәш, бергә хезмәт итүче (яки иткән) кеше.

**СОСЛУЖИ'ТЬ: сослужить службу** — (үтенеч буенча) ярдәм күрсәтү, булышлык итү.

**СОСНА'** *ж.* — нарат.

**СОСНО'ВЫЙ** — 1. нарат ...-ы; *сосновые дрова* — нарат утыны; 2. нарат ..., нарат агачыннан ясалган; *сосновый стол* — нарат өстәл. ◇ **Сосновый бор** — нарат урманы.

**СОСНУ'ТЬ** *сов. разг. фам.* — йоклап алу, бераз йоклап алу.

**СОСНЯ'К** *м. мн.* нет — наратлык, нарат урманы.

**СОСО'К** *м.* — 1. имчәк башы, ими башы; 2. күрү нервысының очы.

**СОСРЕДОТА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. сосредоточить.

**СОСРЕДОТО'ЧЕНИЕ** *ср. мн.* нет — к. сосредоточить, сосредоточиться

**СОСРЕДОТО'ЧЕННОСТЬ** *ж.*: **сосредоточенность вида** — кыяфәтнең җитдилеге; **сосредоточенность взгляда** — карашның бер нәрсәгә (бер җиргә) төбәлгәнлеге; **сосредоточенность внимания** — игътибарның берәр нәрсәгә тупланганлыгы; **смотреть с сосредоточенностью** — җитди игътибар белән карау.

**СОСРЕДОТО'ЧЕННЫЙ** — (бер җиргә) тупланган, җыелган. ◇ **Сосредоточенный взгляд** — (берәр нәрсәгә, бер җиргә) төбәлгән караш, текәлеп карау. **Сосредоточенное внимание** — (берәр нәрсәгә) юнәлдерелгән игътибар, **җитди игътибар. Сосредоточенный вид** — җитди кыяфәт.

**СОСРЕДОТО'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. сосредоточить.

**СОСРЕДОТО'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. сосредоточиться; **2.** *страд.* (бер җиргә) җыелу, туплану.

**СОСРЕДОТО'ЧИЕ** *ср. воен.* — ...җыелган урыны (җире), ...тупланган урыны (җире).

**СОСРЕДОТО'ЧИТЬ** *сов.* — **1.** (бер җиргә) җыю, туплау; *сосредоточить войска* — гаскәрләрне (бер җиргә) туплау; *сосредоточить мысли* — фикерләрне туплау; **2.** туплау, (тулысынча) юнәлдерү; *сосредоточить внимание* — игътибарны туплау.

**СОСРЕДОТО'ЧИТЬСЯ** *сов.* — **1.** (бер җиргә) җыелу, туплану; *войска сосредоточились* — гаскәрләр (бер җиргә) тупландылар; **2.** туплану, (тулысынча) юнәлү; *вся его любовь сосредоточилась на ребёнке* — аның барлык мәхәббәте балага юнәлде; **3.** фикерләрне туплау, игътибарны туплау; *шум мешал мне сосредоточиться* — тавыш игътибарны тупларга комачаулый иде.

**СОСТА'В** *м.* — состав; *войти в состав делегации* — делегация составына керү; *определить состав микстуры* — микстураның составын билгеләү. ◇ **В составе** *чего* — ...-дан гыйбарәт, ...-дан торган; *выслать разведку в составе одного эскадрона* — бер эскадроннан гыйбарәт разведка җибәрергә; *комиссия в составе трёх человек* — өч кешедән гыйбарәт комиссия. **Состав преступления** *право* — җинаять элементлары, җинаять эчтәлеге.

**СОСТАВИ'ТЕЛЬ** *м.* — төзүче; *составитель словаря* — сүзлек төзүче; *составитель поездов* — поездлар составын төзүче.

**СОСТАВИ'ТЕЛЬСКИЙ** — төзүче ...-ы, төзүчегә бирелә торган; *составительский гонорар* — төзүче гонорары.

**СОСТА'ВИТЬ** I *сов.* — **1.** төзү; *составить предложение* — җөмлә төзү; *составить словарь* — сүзлек төзү; **2.** ясау; *составить лекарство* — дару ясау; **3.** (бер җиргә) кую, янәшә кую; тезү, тезеп кую; *составить два стола* — ике өстәлне янәшә кую; *составить посуду в шкаф* — савыт-сабаны шкафка кую; **4.** кушу, ялгау, кушып ялгау; *составить две лестницы* — ике баскычны кушу; **5.** җыю, булдыру, туплау; *составить капитал* — капитал җыю; **6.** булу; тәшкил итү; *расход составит сто рублей* — расходы йөз сум булыр. ◇ **Составить мнение** — фикергә килү. **Составить себе представление** — күз алдына китерү, (билгеле бер) фикергә килү. **Составить счастье** — бәхет бирү, бәхетле итү. **Составить затруднение** — кыенлык тудыру. **Сделать это не составит большого труда** — моны эшләү артык кыен булмас. **Составить себе карьеру** — карьера ясау.

**СОСТА'ВИТЬ** II *сов.* — (түбән) төшерү, төшереп кую; *составить на пол* — идәнгә төшерү.

**СОСТА'ВИТЬСЯ** *сов.* — **1.** төзелү; *составилось предложение* — җөмлә төзелде; **2.** җыелу, туплану, килеп чыгу; *составился большой капитал* — зур капитал тупланды; **3.** килеп чыгу, булу; *составилась тысяча рублей* — мең сум булды; **4.** туу; *составилось мнение* — фикер туды.

**СОСТАВЛЯ'ТЬ** I *несов.* — к. составить I.

**СОСТАВЛЯ'ТЬ** II *несов.* — к. составить II.

**СОСТАВЛЯ'ТЬСЯ** I *несов.* — 1. к. составиться; **2.** *страд.* төзелү, ясалу, кушылу; оештырылу, туплану.

**СОСТАВЛЯ'ТЬСЯ** II *несов. страд.* — (түбән) төшерелү, төшереп куелу.

**СОСТАВНО'Й** — 1. ялгаулы, төрле кисәкләрдән торган; *составное стекло* — ялгаулы пыяла; **2.** составына керә торган; *составной элемент химического соединения* — химик кушылманың составына керә торган элемент.

**СОСТА'РЕТЬСЯ** *сов.* — к. состариться.

**СОСТА'РИТЬ** *сов.* — картайту; *горе состарило его прежде времени* — кайгы аны вакытыннан элек картайткан.

**СОСТА'РИТЬСЯ** *сов.* — картаю.

**СОСТЕГА'ТЬ** *сов. спец.* — **1.** ялгап тегү, ялгап тегеп чыгу, ялгап кую; *состегать два полотнища* — ике кисәк материяне ялгап кую; **2.** (тимер чыбык яки җеп белән) тегү, тегеп кую, тегеп чыгу; *состегать щетину в щётке* — щётканың кылын (тимер чыбык яки җеп белән) тегеп чыгу.

**СОСТЕ'ГИВАТЬ** I *несов. спец.* — к. состегать.

**СОСТЁ'ГИВАТЬ** II *несов. простореч.* — к. состегнуть.

**СОСТЁ'ГИВАТЬСЯ** I *несов. страд. спец.* — **1.** ялгап тегелү, ялгап куелу; **2.** (тимер чыбык яки җеп белән) тегелү, тегеп куелу.

**СОСТЁ'ГИВАТЬСЯ** II *несов. страд. простореч.* — төймәсе ычкындырылу.

**СОСТЕГНУ'ТЬ** *сов. простореч.* — төймәсен ычкындыру.

**СОСТИРА'ТЬ** *сов. простореч.* — юып бетерү, юып китәрү; *состирать грязь с рубашки* — күлмәкнең керен юып бетерү.

**СОСТИРА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — юылу, юылып бетү.

**СОСТИ'РЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. состирать.

**СОСТИ'РЫВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — **1.** к. состираться; **2.** *страд.* юып бетерелү, юып китәрелү.

**СОСТОЯ'НИЕ** *ср.*—1 *только ед. книж.* булу, тору; *состояние в кадровых войсках*— кадровый гаскәрләрдә булу (хезмәт итү); 2. хәл; *раненый в тяжёлом состоянии*— яралы авыр хәлдә; 3. торыш; *состояние погоды* — һава торышы; 4. *устар.* катлау, сословие, дәрәҗә; *люди всякого состояния* — төрле катлау кешеләре; 5. мал, малмөлкәт, дәүләт, байлык; *крупное состояние* — зур байлык. ◇ **В состоянии** *с инф.*— кулым(ң, н)нан килә, ...-а алу, мөмкинлек булу; *я не в состоянии поднять такую тяжесть* — мин мондый авыр әйберне күтәрә алмыйм.

**СОСТОЯ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. байлык, мал-мөлкәтлелек, дәүләтле булу, мал-мөлкәте булу; 2. нигезлелек, нигезләнгәнлек; *проверить состоятельность теории* — теориянең нигезлелеген тикшерү.

**СОСТОЯ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— 1. бай, малмөлкәтле, дәүләтле, мал-мөлкәте булган; хәлле; *состоятельный человек* — мал-мөлкәтле кеше 2. *чаще с отриц.* нигезле, нигезләнгән; *не вполне состоятельное мнение* — бик үк нигезле булмаган фикер.

**СОСТОЯ'ТЬ** *несов.*— 1. тору, гыйбарәт булу; *квартира состоит из трёх комнат и кухни* — квартир өч бүлмәдән һәм кухнядан тора; 2 *офиц.* булып тору, вазифасын үтәү; *состоять заведующим* —мөдир булып тору; 3. *офиц.* булу; *состоять в отпуску*— отпускта булу.

**СОСТОЯ'ТЬСЯ** *сов. книж. офиц.*— булу; *спектакль не состоялся* — спектакль булмады.

**СОСТРА'ГИВАТЬ** *несов.*— к. сострогать.

**СОСТРА'ГИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. сострогаться; 2. *страд.* струклану, струклап алыну, ышкылап алыну.

**СОСТРАДА'НИЕ** *ср. мн.* нет — кызгану, җәлләү, аяу; кайгысын уртаклашу; кеше хәленә керү.

**СОСТРАДА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*—кызганучанлык, җәлләүчәнлек, аяучанлык, кайгыны уртаклашучанлык, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек.

**СОСТРАДА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.*— кызганучан, җәлләүчән, аяучан, кайгыны уртаклашучан, кеше хәленә керүчән, шәфкатьле, мәрхәмәтле.

**СОСТРАДА'ТЬ** *несов. книж. устар.*— кызгану, җәлләү, аяу, кайгысын уртаклашу, кеше хәленә керү.

**СОСТРИГА'ТЬ** *несов.*— к. состричь.

**СОСТРИГА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— китәрелү, алыну, кыркылу (чәч турында).

**СОСТРИ'ТЬ** *сов.*— үткер сүз(ләр) әйтү, тапкыр сүз(ләр) әйтеп ташлау.

**СОСТРИ'ЧЬ** *сов.*— (чәчне) китәрү, алу, алдыру, кырку.

**СОСТРОГА'ТЬ** *сов.*— струклау, ышкылау, струклап алу, ышкылап алу.

**СОСТРОГА'ТЬСЯ** *сов.*— струклану, ышкылану.

**СОСТРОГНУ'ТЬ** *сов. однокр. разг.*— струклап җибәрү, ышкылап җибәрү.

**СОСТРО'ИТЬ** *сов. простореч.*— ясау, төзү, кору; *состроить шалаш* — куыш ясау. ◇ **Состроить рожу** *разг.*— үчекләү, гримаса ясау.

**СОСТРУГА'ТЬ** *сов. обл.*— к. сострогать.

**СОСТРУГА'ТЬСЯ** *сов. обл.*— к. сострогаться.

**СОСТРУ'ГИВАТЬ** *несов. обл.*— к. состругать.

**СОСТРУ'ГИВАТЬСЯ** *несов. обл.*— к. состругаться.

**СОСТРУ'ЖИВАТЬ** *несов. спец. обл.* — к. состружить.

**СОСТРУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд. спец. обл.*— к. сострагиваться.

**СОСТРУ'ЖИТЬ** *сов. спец. обл.*— к. сострогать.

**СОСТРУ'НИВАТЬ** *несов. охот. спец.*— к. струнить.

**СОСТРУ'НИВАТЬСЯ** *несов. страд. охот. спец.*— каеш белән бәйләнү (ауда тотылган хайван борыны турында).

**СОСТРУ'НИТЬ** *сов. охот. спец.*—к. струнить.

**СОСТРЯ'ПАТЬ** *сов.*— к. стряпать.

**СОСТЯЗА'НИЕ** *ср.*— 1. ярыш, ярышу; узыш, узышу; *состязание в беге* — йөгерештә ярышу; *теннисное состязание* — теннис (уены) ярышы; 2. *право, офиц.* бәхәсләшү, җиңешү.

**СОСТЯЗА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *право, офиц.*— (суд процессының) бәхәсләшү (җиңешү) юлы белән алып барылуы, бәхәсләшү (җиңешү) юлы белән алып барыла торган булуы.

**СОСТЯЗА'ТЕЛЬНЫЙ** *право, офиц.*— бәхәсләшү (җиңешү) юлы белән алып барыла торган; *состязательный процесс* — бәхәсләшү юлы белән алып барыла торган суд процессы.

**СОСТЯЗА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. ярышу, узышу; *состязаться в игре на биллиарде* — биллиард уенында ярышу; 2. *право, офиц.* җиңешү, бәхәсләшү.

**СОСУ'Д I** *м.*— савыт; *стеклянный сосуд*— пыяла савыт.

**СОСУ'Д II** *м.*— тамыр; юл, канал; *кровеносные сосуды* — кан тамырлары.

**СОСУ'ДИСТЫЙ** *биол., анат., бот.*— күп тамырлы, күп каналлы.

**СОСУ'ЛЬКА** *ж.*— 1. тамчы бозы, боз сөңгесе; *свисают сосульки с крыш* — өй түбәләреннән боз сөңгеләре салынып төшкән; 2. *обл.* имезлек; *хлебная сосулька* — ипи салынган имезлек; 3. *перен. презрит.* җебегән (кеше турында).

**СОСУ'Н** *м.*— 1. имүче, имә торган (мәсәлән, колын); 2. *простореч. шутл.* имчәк баласы; 3. *простореч. неодобр.* имәргә яратучы бала, теләсә ни имүче бала; 4. *тех.* су суыргыч; *сосуны бумагоделательной машины* — кәгазь ясау машинасының су суыргычлары.

**СОСУЩЕСТВОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— к. сосуществовать.

**СОСУЩЕСТВОВА'ТЬ** *несов. книж.*— бер үк вакытта яшәү, янәшә яшәү.

**СОСЦЕВИ'ДНЫЙ** *книж. спец.*— имчәк башысыман.

**СОСЧИТА'ТЬ** *сов.*— санау, санап чыгу.

**СОСЧИТА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— к. рассчитаться 1, 2.

**СОСЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.*— к. сосчитать.

**СОСЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. сосчитаться; 2. *страд.* саналу, санап чыгылу.

**СОТВОРИ'ТЬ** *сов. книж.*— к. творить 1.

**СОТВОРИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — к. твориться I в 1 знач.

**СОТВО'РЧЕСТВО** *ср мн.* нет, *книж.* — иҗатташлык, бергә иҗат итү.

**СОТЕ'** *ср. нескл.*— соте (соус белән әзерләнгән ашамлык).

**СОТЕ'ЙНИК** *м.* — сотейник, дүрт кырлы таба (соте́ хәзерләү өчен кулланыла).

**СО'ТЕННАЯ** *ж. в знач. сущ. простореч.*— йөз сумлык (кәгазь акча).

**СО'ТЕННЫЙ** — 1. *истор.* йөз ...-ы; *сотенная голова* — йөз башы (йөзбашы); 2. *простореч.* йөз сумлык...; *сотенный билет* — йөз сумлык кәгазь акча.

**СОТЕ'РН** *м. мн.* нет — сотерн (виноград виносының ак төстәге бер төре).

**СО'ТКА** *ж.* — сотый (берәр нәрсәнең йөздән бер өлеше).

**СОТКА'ТЬ** *сов.*— к. ткать.

**СОТКНУ'ТЬ** *сов.* — к. стыкать.

**СО'ТНИК** *м.* — 1. *истор.* йөзбашы; 2. *дореwол.* сотник (казачий гаскәрләрендә пехота поручигы чинына туры килгән офицер чины).

**СО'ТНИЧИХА** *ж. устар.* — йөзбашы хатыны; сотник хатыны.

**СО'ТНЯ** *ж.*— 1. йөз, йөз данә; *сотня яиц* — йөз йомырка; 2. *простореч.* йөз сум; *две сотни истратил* — ике йөз сум тоттым; 3. *простореч. (сторублёвка)* йөз сумлык акча; 4. *чаще мн. разг.* йөзләп, йөзләрчә, йөзләгән; *сотни раз я напоминал тебе об этом* — бу турыда йөзләрчә тапкыр әйтә килдем; *сотни автомобилей* — йөзләгән автомобильләр; 5. *истор. (войсковое подразделение)* йөз; 6. *дореwол.* сотня (казачийларда гаскәри берәмлек); 7. *истор.* сотня (Москва Русенда — һөнәрчеләрнең, сәүдәгәрләрнең, промышленникларның цех оешмасы). ◇ **Чёрная сотня** — к. чёрный.

**СОТНЯ'ГА** *ж. простореч. фам.* — к. сотня 2.

**СОТОВА'РИЩ** *м. книж. устар., теперь разг.* — иптәш.

**СОТОВА'РИЩЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — к. товарищество 1.

**СОТОВИ'ДНЫЙ** *спец.*— кәрәзсыман.

**СО'ТОВЫЙ** *спец.* — 1. кәрәз ...-ы, кәрәзле; *сотовый мёд* — кәрәзле бал; 2. *радио* к. сотовидный.

**СОТРАПЕ'ЗНИК** *м. устар. книж., теперь шутл.* — табындаш, ашташ.

**СОТРАПЕ'ЗНИЧАТЬ** *несов. книж. устар.* — бер табында ашау.

**СОТРУ'ДНИК** *м.*, **СОТРУ'ДНИЦА** *ж.*— 1. *книж.* сотрудник, хезмәттәш, бергә хезмәт итүче; ярдәмче, булышчы; *Даль составил свой словарь один, без сотрудников* — Даль үзенең сүзлеген бер үзе, ярдәмчесез төзегән; 2. сотрудник, хезмәткәр; *научный сотрудник* — гыйльми сотрудник; *сотрудник газеты* — газета сотрудникы.

**СОТРУ'ДНИЧАТЬ** *несов.*—1. бергә эшләү, бергә хезмәт итү; ярдәмче булу; 2. эшләү, катнашу; язу; *сотрудничать в газете* — газетада эшләү.

**СОТРУ'ДНИЧЕСТВО** *ср. мн* нет —1. *(действие)* к. сотрудничать; 2. хезмәттәшлек.

**СОТРЯСА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. *устар.* селкетү, дер селкетү; *ветер сотрясал и ломал деревья* — җил агачларны дер селкетә һәм сындыра иде; 2. тетрәтү, яңгырату; *сотрясать воздух* — һаваны тетрәтү; 3. *ритор.* калтырату, дерелдәтү; *сотрясать сердца* — йөрәкләрне калтырату.

**СОТРЯСА'ТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. *устар.* дерелдәү, калтырану; *сотрясаться от рыданий* — иңрәп елаудан бөтен тәне белән калтырану; 2. тетрәү, яңгырау; *воздух сотрясался от криков* — кычкырган тавышлардан һава тетри иде; 3. *ритор.* өзелү, әрнү; *душа его сотрясалась от горя* — кайгыдан аның үзәге өзелә иде.

**СОТРЯСЕ'НИЕ** *ср книж. устар. спец.* — тетрәү; тетрәп селкенү.

**СОТРЯСТИ'** *сов. книж. устар.* — к. сотрясать 2, 3.

**СОТРЯСТИ'СЬ** *сов. книж. устар.* — к. сотрясаться.

**СО'ТСКИЙ** *м.*— сотский (1. *дореwол.* авыл полициясе ярдәмчесе итеп куелган крестьян; 2. *истор.* Москва Русенда — һөнәрчеләрнең, сәүдәгәрләрнең, промышленникларның цех оешмасында йөздән сайланып куела торган староста).

**СО'ТЫ** *только мн.* — кәрәз.

**СО'ТЫЙ** — йөзенче.

**СОУ'ЗНИК** *м.*, **СОУ'ЗНИЦА** *ж. книж. устар.* — зиндандаш, бергә тоткында булган кеше.

**СОУМЫ'ШЛЕННИК** *м.*, **СОУМЫ'ШЛЕННИЦА** *ж. книж.*— җинаятьтәш, бергә җинаять эшләгән кеше, бергә явызлык эшләгән кеше.

**СОУМЫ'ШЛЕННЫЙ** *книж.*—берничә кеше хәзерләгән (җинаять, явызлык), җинаятьтәшләр тарафыннан уйланган.

**СО'УС** *м.* — 1. соус (а. ашамлыкларга салына торган сыек тәмләткеч; б. *живоп.* графит һәм сланецтан әзерләнгән, кисточка белән рәсем төшерүдә кулланыла торган масса); 2. *перен. разг. фам.* маска, хәйлә; *преподнести неприятную новость под соусом дружественного сообщения* — дусларча хәбәр сөйләү маскасы астында (дусларча хәбәр сөйләгән булып) күңелсез хәбәр сөйләү.

**СО'УСНИК** *м.*, **СО'УСНИЦА** *ж.* — соус савыты.

**СОУЧА'СТВОВАТЬ** *несов. книж. офиц.*— бергә катнашу.

**СОУЧА'СТНИК** *м.*, **СОУЧА'СТНИЦА** *ж. книж. офиц.* — катнашучы, (бергә) катнашкан кеше; *соучастник в преступлении* — җинаятьтә катнашкан кеше.

**СОУЧЕНИ'К** *м.*, **СОУЧЕНИ'ЦА** *ж. книж. устар.* — сабакташ, шәрик.

**СОФА'** *ж. нескл. устар.* — соффә (диванның бер төре).

**СОФИ'ЗМ** *м. книж.* — софизм (формаль яктан дөрес кебек күренгән ялган фикри нәтиҗә, ялган фикерләү).

**СОФИ'СТ** *м. книж.* — софист 1. *(неодобр.* софизмнарга нигезләнеп фикер йөртүче; 2. *истор. филос.* безнең эрага кадәр 5—4 гасырларда борынгы Греция мәгърифәтчеләре төркеменнән философ).

**СОФИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.* — софистика (1. софизмнарга нигезләнеп фикер йөртү; софизмнардан файдалану; 2. *истор. филос.* софистлар тәгълиматы).

**СОФИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — софистик, софизмнарга нигезләнгән, софизмнарга нигезләнеп ...; *софистическое рассуждение* — софизмнарга нигезләнеп фикер йөртү.

**СОФФИ'Т** *м.* — софит (1. *архит.* а́рканың түбәнге өлеше; 2. *театр.* декорациядә — түшәм; 3. *театр.* сәхнәне өстән яктырту өчен хезмәт итә торган лампалар).

**СОХА'** *ж.* — сука.

**СОХА'ТЫЙ** — 1. ике аерылы, ике ябьле; *сохатая жердина* — ике аерылы колга; 2. тармаклы мөгезле; *сохатый олень* — тармаклы мөгезле болан; 3. *в знач. сущ.* поши.

**СО'ХНУТЬ** *несов.* — 1. кибү; *бельё сохнет на чердаке* — кер чарлакта кибә; 2. көю, кору (үсемлекләр турында); 3. *перен.* ябыгу, кибү; *сохнуть от тоски* — сагыштан кибү; 4. *перен.* (гыйшык утында) яну, кибү, саргаю; *по Груне я сохну, молодец* (А. Кольцов) — Груня дип янам мин, егеткәй.

**СОХРАНИ'ТЬ** *сов.* — 1. саклау, саклап калу, саклап алып калу; *сохранить своё здоровье* — саулыгыңны саклау; 2. калдыру; *я сохранил за собой право вернуться к этому вопросу* — мин үземдә бу мәсьәләгә янадан кайту хокукын калдырдым.

**СОХРАНИ'ТЬСЯ** *сов.* — саклану, сакланып калу.

**СОХРА'ННО** *нареч. канц.* — бөтен көе, бозылмыйча, яхшы хәлдә, исән-сау.

**СОХРА'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *офиц. канц.* — сакланганлык, саклану; иминлек.

**СОХРА'ННЫЙ** — 1. *устар.* (*тщательно сберегаемый*) саклап килгән, саклана торган; 2. *устар.* имин, куркынычсыз, яшерен; *спрятать в сохранном месте* — имин җиргә яшерү. ◇ **Сохранная расписка** *офиц.* — саклык распискасы (кыйммәтле әйберләрне сакларга алу турында бирелгән таныклык).

**СОХРАНЯ'ТЬ** *несов.* — к. сохранить.

**СОХРАНЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. сохраниться.

**СОЦВЕ'ТИЕ** *ср. бот.* — оешма чәчәк; укмаш чәчәк.

**СОЦДО'ГОВОР** *м.* — социалистик договор, соцдоговор.

**СОЦИА'Л-ДЕМОКРА'Т** *м. полит.* — социал-демократ (социал демократия тарафдары, социал-демократлар партиясе члены).

**СОЦИА'Л-ДЕМОКРАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — социал-демократизм (социал-демократиянең идеологиясе һәм тактикасы).

**СОЦИА'Л-ДЕМОКРАТИ'ЧЕСКИЙ** *полит.* — социал-демократик, социал-демократлар ...-ы; *социал-демократическая партия* — социал-демократлар партиясе.

**СОЦИА'Л-ДЕМОКРА'ТИЯ** *ж. мн.* нет, *полит.* — 1. социал-демократия (халыкара эшчеләр хәрәкәтендә политик юнәлеш: соңыннан бу юнәлеш оппортунистик агымга әверелеп, пролетариатның революцион хәрәкәтенә каршы алып барыла торган көрәштә капитализмның төп таянычына әйләнде); 2. социал-демократлар партиясе.

**СОЦИАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон. полит.* — (пролетариат диктатурасы шартларында) социализация ясау (үткәрү), социалистик милеккә әверелдерү.

**СОЦИАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов.* социалистик милеккә әверелү; 2. *несов. страд.* социализация ясалу (үткәрелү); социалистик милеккә әверелдерелү (пролетариат диктатурасы шартларында).

**СОЦИАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — социализм (1. пролетариат революциясенең җиңүе, буржуазия хакимлегенең бетерелүе һәм пролетариат диктатурасының урнашуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән, коммунизмның беренче фазасы булган җәмгыять һәм дәүләт строе; аның җитештерү мөнәсәбәтләренең нигезендә җитештерү чараларына иҗтимагый милек ята; бу стройның төп принцибы: „һәркемнән сәләтенчә, һәркемгә хезмәтенчә"; 2. социалистик җәмгыять төзү турындагы тәгълимат, фән).

**СОЦИА'Л-ИМПЕРИАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит. презрит.* — социал-империализм (оппортунизмның бер төре, үз иленең империалистик хөкүмәтенә булышлык итү политикасы).

**СОЦИА'Л-ИМПЕРИАЛИ'СТ** *м. полит. презрит.* — социал-империалист, социал-империализм политикасын үткәрүче.

**СОЦИАЛИ'СТ** *м.* — социалист (1. социализм тарафдары; 2. социалистлар партиясе члены).

**СОЦИАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. социалистик; *Союз Советских Социалистических Республик есть социалистическое государство рабочих и крестьян* (Конституция СССР) — Совет Социалистик Республикалар Союзы — эшчеләрнең һәм крестьяннарның социалистик дәүләте; 2. социалистлар ...-ы; *социалистическая партия* — социалистлар партиясе; 3. социализм ...-ы; *социалистическое учение* — социализм тәгълиматы.

**СОЦИАЛИ'СТКА** *ж.* — к. социалист.

**СОЦИАЛИ'СТ-РЕВОЛЮЦИОНЕ'Р** *м. полит.* — социалист-революционер, эсер (марксизмга ачыктан-ачык дошман булган һәм кулаклар интересын чагылдырган, 1902 елда барлыкка килгән вак буржуаз партия).

**СОЦИА'Л-ПАТРИО'Т** *м. полит. презрит.* — социал-патриот (к. социал-шовинист).

**СОЦИА'Л-ПАТРИОТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит. презрит.* — к. социал-шовинизм.

**СОЦИА'Л-ПАЦИФИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит. презрит.*—социал-пацифизм (оппортунизмның бер төре; социал-демократларның, пацифизм флагы астына яшеренеп, үз иле буржуазиясенең империалистик политикасын яклау тактикасы).

**СОЦИА'Л-ПАЦИФИ'СТ** *м. полит. презрит.* — социал-пацифист (социал-пацифизм политикасын үткәрүче).

**СОЦИ'АЛ-СОГЛАША'ТЕЛЬ** *м. полит. презрит.* — социал-соглашатель (к. соглашатель).

**СОЦИА'Л-СОГЛАША'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *полит. презрит.* — социал-соглашательлек (к. соглашательство).

**СОЦИА'Л-ШОВИНИ'ЗМ** *м. полит. презрит.* — социал-шовинизм (оппортунизмның беренче бөтендөнья сугышы чорында барлыкка килгән төре; социал-демократия тарафыннан үз иленең капиталистик хөкүмәте үткәргән империалистик политикасын хуплау).

**СОЦИА'Л-ШОВИНИ'СТ** *м. полит. презрит.* — социал-шовинист (социал-шовинизм политикасын үткәрүче социал-демократ).

**СОЦИА'ЛЬНО** *нареч.* — социаль яктан, җәмгыять өчен, иҗтимагый яктан; *социально чуждый элемент* — җәмгыять өчен чит элемент.

**СОЦИА'ЛЬНО-БЫТОВО'Й** —иҗтимагый-көнкүреш ...-ы; социаль-көнкүреш ...-ы; *социально-бытовая тема* — социаль-көнкүреш темасы.

**СОЦИА'ЛЬНО ОПА'СНЫЙ** — социаль яктан куркынычлы (зарарлы), җәмгыять өчен куркынычлы.

**СОЦИА'ЛЬНО-ПОЛИТИ'ЧЕСКИЙ** *право* — иҗтимагый-политик, социаль-политик.

**СОЦИА'ЛЬНЫЙ** — **1.** иҗтимагый; *социальные науки* — иҗтимагый фәннәр; **2.** социаль; *социальный переворот* — социаль переворот.

**СОЦИО'ЛОГ** *м.* — социолог, социология белгече.

**СОЦИОЛОГИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *науч.* — социологизм (иҗтимагый күренешләрне буржуаз социология күзлегеннән чыгып аңлату).

**СОЦИОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — социология ...-ы, социологик; *социологический метод* — социологик метод.

**СОЦИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — социология (җәмгыять һәм аның үсеше турындагы тәгълимат).

**СОЦСОРЕВНОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — социалистик ярыш.

**СОЦСТРА'Х** *м. мн.* нет (социальное страхование) — соцстрах, социаль страхование.

**СОЧЁНЫЙ** — сыгылган, сыккан, агызылган; *сочёный мёд* — агызылган бал.

**СОЧЕТА'НИЕ** *ср.* — **1.** *(действие)* к. сочетать; **2.** *(действие и состояние)* к. сочетаться; **3.** *только мн. мат.* оештырмалар.

**СОЧЕТА'ТЕЛЬНЫЙ** *науч.* — **1.** катлаулы; *сочетательный рефлекс* — катлаулы рефлекс; **2.** *мат.* оештыру ...-ы; *сочетательный закон* — оештыру законы.

**СОЧЕТА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — берләштерү, кушу, бергә алып бару, бәйләү, бәйләп алып бару; баглау; *сочетать теорию с практикой* — теорияне практика белән баглау (бергә баглау).

**СОЧЕТА'ТЬСЯ** — **1.** *сов.* и *несов.* берләшү, кушылу, бергә туры килү, (бер үк вакытта) булу; *в нём сочеталось несколько талантов* — аңарда берничә талант бар иде; **2.** *несов.* ярашу, туры килү, туры килеп тору; *одно не сочетается с другим* — берсе-берсенә туры килми; **3.** *страд.* берләштерелү, кушылу, бәйләп алып барылу; бергә алып барылу. ◇ **Сочетаться браком** *устар.* — никахланышу.

**СО'ЧИВО** *ср. мн.* нет, *обл.* — **1.** орлык согы, орлык мае; **2.** шул сокны салып пешерелгән аш.

**СОЧИНЕ'НИЕ** *ср.* — **1.** *только ед. (действие)* к. сочинить; 2. әсәр; *сочинения Гоголя* — Гоголь әсәрләре; **3.** сочинение; *классное сочинение* — класста язылган сочинение; **4.** *только ед. грам.* тезү юлы белән төзү; *сочинение предложений* — тезү юлы белән җөмләләр төзү.

**СОЧИНЁННЫЙ** *книж.* — **1.** *устар.* язылган, иҗат ителгән; **2.** уйлап чыгарылган, үзеннән чыгарылган, ясалма, уйдырма.

**СОЧИНИ'ТЕЛЬ** *м.*, **СОЧИНИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — **1.** *устар. (писатель)* әдип, язучы; **2.** *разг. пренебр.* ялганчы, уйдырмачы; булмаганны уйлап чыгаручы; *не верьте ему, он известный сочинитель!* — ышанмагыз аңа, ул билгеле бер ялганчы! ◇ **Сочинитель сплетин** *разг. пренебр.* — гайбәт чыгаручы, гайбәтче, гайбәт капчыгы.

**СОЧИНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *грам.* — **1.** тезүче; *сочинительные союзы* — тезүче теркәгечләр; **2.** тезмә...; *сочинительная конструкция* —тезмә конструкция.

**СОЧИНИ'ТЕЛЬСКИЙ** *устар.* — язучылык...-ы; язучы...-ы; *сочинительский талант* — язучылык таланты.

**СОЧИНИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — **1.** *устар. (писательство)* язучылык, әдиплек; **2.** *разг. пренебр.* иҗатчылык, юкны уйлап чыгару, булмаганны уйлап чыгару, хыяллану.

**СОЧИНИ'ТЬ** *сов.* — **1.** *устар.* язу, иҗат итү; *сочинить пьесу* — пьеса язу; **2.** (ялган хәбәр) чыгару, (булмаганны) уйлап чыгару, үзеннән чыгару; *сочинить сплетню* — гайбәт чыгару; **3.** *разг. фам. (солгать)* ялганлау; **4.** *грам.* тезү юлы белән җөмләләр төзү. ◇ **Сочинить себе** *разг. фам.* — үзеннән-үзе уйлап чыгару, күңеленә салу, үзенүзе ышандыру.

**СОЧИНЯ'ТЬ** *несов.* —к. сочинить.

**СОЧИНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — **1.** *устар.* язылу, иҗат ителү; **2.** уйлап чыгарылу, үзеннән чыгарылу.

**СОЧИ'ТЬ** *несов.* —тамызу, саркыту; агызу.

**СОЧИ'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** таму, сарку; агу; **2.** *страд.* агызылу; саркытылу.

**СОЧЛЕ'Н** *м. книж.* — оешмадаш, бер үк оешма члены.

**СОЧЛЕНЕ'НИЕ** *ср.* — **1.** *только ед. книж.*

*(действие)* к. сочленить; 2. *книж.* тоташтырылган (ялганган, кушылган, буынтыкланган) нәрсә; 3. *анат.* буынтыкланыш.

**СОЧЛЕНИ'ТЬ** *сов. книж.* — буынтыклау; беркетү, ялгау, тоташтыру, кушу.

**СОЧЛЕНИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — буынтыклану, буынтыклашу; тоташу, кушылу, ялгану.

**СОЧЛЕНЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. сочленить.

**СОЧЛЕНЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. сочлениться; 2. *страд.* буынтыклану, ялгану, тоташтырылу, кушылу.

**СО'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. сусыллык; *персики отличаются сочностью* — шапталулар сусыллыклары белән аерылып тора (шапталулар бик сусыл була); 2. *перен.* образлылык, мәгънәлелек; *сочность стиля* — стильнең образлылыгы.

**СО'ЧНЫЙ** — 1. *бот.* сусыл; *сочные растения* — сусыл үсемлекләр; 2. *перен.* ачык; *сочные краски* — ачык буяулар; 3. *перен.* ачык яңгырашлы, яңгыравыклы, көчле; *сочный голос* — яңгыравыклы тавыш; 4. *перен.* образлы, мәгънәле; *сочное выражение* — образлы тәгъбир.

**СОЧУ'ВСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — теләктәшлек, теләктәшлек күрсәтеп (белдереп) эшләнгәнлек; *сочувственность отзыва* — отзывның теләктәшлек күрсәтеп язылганлыгы.

**СОЧУ'ВСТВЕННЫЙ** *книж.* — 1. теләктәшле; теләктәшлек күрсәткән (белдергән), теләктәшлек күрсәтеп (белдереп) эшләнгән; *сочувственный отзыв* — теләктәшлек күрсәтеп язылган отзыв; 2. *устар.* йомшак күңелле, кайгыны уртаклашучан, кызганучан.

**СОЧУ'ВСТВИЕ** *ср. мн.* нет — к. сочувствовать.

**СОЧУ'ВСТВОВАТЬ** *несов.* — 1. кайгыны уртаклашу, хәленә керү, кызгану; 2. теләктәшлек итү, теләктәшлек күрсәтү, яклау.

**СОШЕ'СТВИЕ** *ср.* — к. сойти I в 1 зн.

**СО'ШКА** *ж.* — 1. *разг.* к. соха 1; 2. терәк, терәвеч; сошка (мылтыктан, пулемёттан атканда кулланыла торган терәк). ◇ **Мелкая сошка** — к. мелкий.

**СОШНИ'К** *м.* — 1. *с.-х.* сука тимере; 2. *с.-х.* төрән (сабанда); 3. *с.-х.* теш (чәчү машинасында); 4. *воен.* сошник, терәвеч (артиллерия орудиеләрендә); 5. *анат.* төрән сөяк (борынның эчке өлешен икегә бүлә торган вертикаль сөяк).

**СО'ШНЫЙ: сошные люди** *истор.* — игенчеләр (борынгы Русьта); **сошное письмо** *истор.* — җир язу (борынгы Русьта сука башыннан налог салу системасы).

**СОЩИПА'ТЬ** *сов. разг.* — чеметеп алып бетерү, чеметеп өзеп бетерү.

**СОЩИПНУ'ТЬ** *сов. однокр. разг.* — чеметеп өзү, чеметеп алу.

**СОЩУ'РИВАТЬ** *несов.* — к. сощурить.

**СОЩУ'РИВАТЬСЯ** *несов.* — к. сощуриться.

**СОЩУ'РИТЬ** *сов.* — к. прищурить.

**СОЩУ'РИТЬСЯ** *сов.* — к. прищуриться.

**СОЮ'З I** *м.* — 1. союз, берләшмә; 2. *только мн. сапож.* к. союзка.

**СОЮ'З II** *м. грам.* — теркәгеч.

**СОЮ'ЗИТЬ** *несов. сапож.* — к. обсоюзить.

**СОЮ'ЗКА** *ж. сапож.* — итек башы, ботинка башы.

**СОЮ'ЗНИК** *м.* — 1. союздаш; 2. *только мн.* союзниклар (1914—18 еллардагы империалистик сугышта Германиягә каршы дәүләтләр).

**СОЮ'ЗНИЦА** *ж.* — к. союзник 1.

**СОЮ'ЗНИЧЕСКИЙ** — союзниклар...-ы, союздашлар...-ы, союздашлык...-ы; *союзнические обязанности* — союздашлык бурычлары.

**СОЮ'ЗНО-РЕСПУБЛИКА'НСКИЙ** *офиц.* — союз-республика...-ы; союз-республика күләмендәге; *союзно-республиканские министерства* — союз-республика министрлыклары.

**СОЮ'ЗНЫЙ** I — 1. союз...-ы; *союзный договор* — союз договоры; *союзный билет* — союз билеты (ягъни профсоюз билеты); 2. союздаш; *союзные республики* — союздаш республикалар; 3. *спец.* катламлы, катлам-катлам итеп ясалган; *союзная пастила* — катламлы пастила.

**СОЮ'ЗНЫЙ** II *грам.* — теркәгечле; *союзная конструкция* — теркәгечле конструкция.

**СО'Я** I *ж. мн.* нет — соя (1. берьеллык кузаклы үсемлек; 2. шул үсемлекнең орлыгыннан хәзерләнгән аш тәмләткеч).

**СО'Я** II *ж. зоол.* — к. сойка.

**СПАДА'ТЬ** *несов.* — к. спасть 3, 4.

**СПАДА'ТЬСЯ** *несов. обл.* — (күләме ягыннан) кечерәю, кимү, кысылу, кечерәя бару, кими бару, кысыла бару.

**СПАЗМ** *м.*, **СПА'ЗМА** *ж.* — 1. спазма (үңәчнең, эчәкләрнең, ашказанының, бугазның, кан тамырларының кысылуы); 2. күзән җыеру, тартышу (кул-аякның).

**СПАЗМАТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — 1. спазма...-ы, спазматик; *спазматический припадок* — спазматик өянәк; 2. спазма сәбәпле, (спазма аркасында) килеп чыккан, спазмалы; буылып-буылып...; *спазматический кашель* — буылып-буылып йөткерү; 3. сулкылдап-сулкылдап...; *спазматические рыдания* — сулкылдап-сулкылдап елау.

**СПА'ИВАТЬ** I *несов.* — к. споить.

**СПА'ИВАТЬ** II *несов.* — к. спаять.

**СПА'ИВАТЬСЯ** I *несов. страд.* — 1. эчерелү, эчереп бетерелү; 2. аракы эчәргә өйрәтелү.

**СПА'ИВАТЬСЯ** II *несов.* — 1. к. спаяться; 2. *страд.* кургаш коеп ябыштырылу.

**СПАЙ** *м. спец.* — 1. *только ед.* к. спайка 1; 2. к. спайка 2.

**СПА'ЙКА** *ж.* — 1. *только ед. (действие)* к. спаять, спаяться; 2. *спец.* ябышкан җир; ябыштырылган җир (урын), кургаш коеп ябыштырылган җир (урын); *трубка сломалась в самой спайке* — көпшә нәкъ ябыштырылган җиреннән сынды; 3. *только ед. перен. разг. (единение)* бердәмлек, оешканлык, дуслык.

**СПАЙНОЛЕПЕ'СТНЫЕ** *бот.* — тоташ таҗ яфракчыклылар.

**СПА'ЙЩИК** *м. спец.* — кургаш коеп ябыштыручы.

**СПА'ЛЗЫВАТЬ** *несов.* — шуып төшү.

**СПАЛИ'ТЬ** *сов. просторец.* — 1. яндыру, яндырып бетерү; *спалить лес* — урманны яндыру; 2. көйдерү, көйдереп алу, яндырып алу; *спалить волосы* — чәчне көйдерү; 3. яндыру, пешерү; *спалить лицо* — битне пешерү; *спалило спину* — (кояш) арканы яндырды.

**СПА'ЛЬНАЯ** *ж. в. знач. сущ. обл., устар.* — к. спальня.

**СПА'ЛЬНЫЙ** — йокы ...-ы, йоклау ...-ы; *спальная комната* — йокы бүлмәсе. ◇ **Спальные принадлежности** — урын-җир әйберләре. **Спальный вагон** — спальный вагон.

**СПА'ЛЬНЯ** *ж.* — 1. йокы бүлмәсе; 2. йокы бүлмәсе мебеле; *спальня красного дерева* — кызыл агачтан ясалган йокы бүлмәсе мебеле.

**СПАНЬЁ** *ср. мн.* нет — к. спать.

**СПАРДЕ'К** *м. мор.* — спардек, югарыгы палуба (гадәттә өч палубалы судноларда).

**СПАРДЕ'ЧНЫЙ** *мор.* — спардеклы; *спардечное судно* — спардеклы судно.

**СПА'РЕННЫЙ: спаренная работа** — парлап эшләү; **спаренная ось** *ж.-д.* — спарник белән тоташтырылган күчәр (паровозда); **спаренная езда** — сменалап йөртү (бер үк паровозны, автомашинаны һ. б. ике бригаданың яки ике кешенең сменалап йөртүе).

**СПАРЖА'** *ж. мн.* нет — 1. *бот.* давыл үләне, әспе чыбыгы, торна җиләге; 2. спаржа (шул үсемлекнең ашауга китә торган тамыры).

**СПА'РИВАТЬ** *несов.* — к. спарить.

**СПА'РИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. спариться; 2. *страд.* чаптырылу, качырылу.

**СПА'РИТЬ** *сов.* — 1. *обл.* парын сайлап табу; 2. *спец. (случить)* чаптыру, качыру, аталандыру, каплату; 3. *просторец.* парлаштыру, пар итеп билгеләү (бергә эшләү өчен).

**СПА'РИТЬСЯ** *сов.* — 1. *спец.* (*о самце и самке*) чабу, качу, аталану; 2. *просторец.* парлашу, парлашып эшләү, пар-пар булып эшләү.

**СПА'РНИК** *м. ж.-д.* — спарник (паровозның йөртүче көпчәкләренә йөртелүче көпчәкләрен тоташтыра торган стержень).

**СПАРТАКИА'ДА** *ж.* — спартакиада (массовый рәвештә үткәрелә торган зур спорт ярышы).

**СПАРТА'НЕЦ** *м.*, **СПАРТА'НКА** *ж.* — спартан (1. *истор.* борынгы грек дәүләте Спарта гражданы, спарталы; 2. үзен мохтаҗлыкларда яшәп чыныктыручы, тормышта иң аз һәм иң кирәк нәрсәләр белән генә чикләнүче кеше).

**СПАРТА'НСКИЙ** — 1. Спарта...-ы; *спартанское государство* — Спарта дәүләте; 2. спартан...-ы, спарталы...-ы; *спартанские привычки* — спартан гадәтләре. ◇ **Спартанский образ жизни** — спартаннарча яшәү, спартаннар тормышы.

**СПА'РХИВАТЬ** *несов.* — к. спорхнуть.

**СПА'РЫВАТЬ** *несов.* — к. спороть.

**СПА'РЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. спороться; 2. *страд.* сүтеп алыну.

**СПАСА'ТЕЛЬ** *м. спец.* — 1. коткаручы (мәсәлән, суга батучыны); 2. суга батучыларны коткару судносы, коткаручы судно.

**СПАСА'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — суга батучыларны коткару...-ы; коткаручы...; *спасательная лодка* — суга батучыларны коткару көймәсе.

**СПАСА'ТЬ** *несов.* — к. спасти.

**СПАСА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. спастись; 2. *страд.* коткарылу, саклап калдырылу.

**СПАСЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. (*действие*) к. спасти; 2. котылу, котылу чарасы, котылу юлы.

**СПАСИ'БО** — рәхмәт. ◇ **За (одно) спасибо (сделать что-н.)** *разг. фам.* — бушка, рәхмәт әйткән өчен (эшләү).

**СПАСИ'БОЧКИ, СПАСИ'БОЧКО** *просторец. фам.* — к. спасибо.

**СПАСИ'ТЕЛЬ** *м.*, **СПАСИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — коткаручы, коткарып алып калучы; ярдәм кулын сузучы.

**СПАСИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — коткаручанлык, коткара торган булу, коткара торганлык.

**СПАСИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж.* — коткара торган, коткару ...-ы; котылу...-ы; *спасительное средство* — коткару чарасы.

**СПАСОВА'ТЬ** *сов.* — 1. уйнамау, уенда катнашмау, катнашмый калу (карта уенында); 2. *перен.* шүрләү, шүрләп калу.

**СПАСТИ'** *сов.* — коткару, коткарып алып калу. ◇ **Спасти положение** — коткару (кыен хәлдән чыгу юлын табу яки шул юлны табуда ярдәм күрсәтү).

**СПАСТИ'СЬ** *сов.* — котылу, котылып калу.

**СПАСТИ'ЧЕСКИЙ** — к. спазматический

**СПАСТЬ** *сов.* — 1. коелу, коелып бетү; *все листья уже спали с деревьев* — агачларның барлык яфраклары коелып бетте инде; 2. төшү, ычкыну; *кольцо спало с пальца* — йөзеге бармагыннан төшкән; 3. кимү; *вода в реке спала* — елгада су кимегән; 4. кайту; *жара спала* — эссе кайтты. ◇ **Спасть с голоса** *разг.* — тавышын югалту (җырчы турында). **Спасть с тела или с лица** *просторец.* — ябыгу.

**СПАТЬ** *несов.* — йоклау. ◇ **Лавры не дают спать чьи кому** — (берәрсенең) лаврлары аңа йокы бирми. **Спать вечным или могильным сном или сном могилы** *книж. поэт.* — мәңге йокыга китү (үлү мәгънәсендә). (**Только или и) спать и видеть** *разг.* — (берәр нәрсәне) төштә дә күрү, (берәр нәрсә белән) бик нык хыяллану.

**СПА'ТЬСЯ** *несов безл. разг.* — йоклый алу, йокы алу, йоклап булу, йокы керү, йоклану; *не спится* — йоклап булмый (күзгә йокы керми).

**СПАХА'ТЬ** *сов.* — сөреп тигезләү, сукалап тигезләү.

**СПА'ХИВАТЬ** *несов.* — к. спахать.

**СПА'ХИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — сөреп тигезләнү, сукалап тигезләнү.

**СПА'ЯННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ябышканлык, береккәнлек, укмашканлык; 2. *перен.* бердәмлек, берләшкәнлек, бәйләнештә булу; *крепкая спаянность с массами* — массалар белән тыгыз бәйләнештә булу.

**СПА'ЯННЫЙ** — 1. кургаш коеп ябыштырылган; 2. *перен.* ябыштырылган, берекквн, укмаштырылган; 3. *перен.* берләшкән, бәйләнештә булган.

**СПАЯ'ТЬ** *сов.* — 1. кургаш коеп ябыштыру; *спаять концы проволочки* — тимер чыбыкның очларын кургаш коеп ябыштыру; 2. *перен. (слепить)* ябыштыру, нык беркетү, укмаштыру; 3. *перен. ритор.* берләштерү; *спаять коллектив* — коллективны берләштерү.

**СПАЯ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. паять ителү; *концы проволочки спаялись* — тимер чыбыкның очлары паять ителде; 2. *перен.* берберсенә ябышу, бер-берсенә ябышып кату; берегү, укмашу; *льдины спаялись* — боз кисәкләре бер-берсенә ябышып катканнар; 3. *перен. ритор.* берләшү, бер бөтенгә әйләнү; *коллектив спаялся* — коллектив берләште.

**СПЕВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. спеться.

**СПЕ'ВКА** *ж.* — спевка, репетиция (җырчылар, хор репетициясе).

**СПЕКА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — спекальщик, кыздырып укмаштыручы.

**СПЕКА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.* — 1. кызып укмашу; *для получения клинкера кирпич обжигают до спекания* — клинкер ясау өчен кирпечне кызып укмашканчы яндыралар; 2. *(действие)* к. спекать.

**СПЕКА'ТЬ** *несов. тех.* — кыздырып укмаштыру.

**СПЕКА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. спечься; 2. *страд. тех.* (кыздырып) укмаштырылу.

**СПЕКТА'КЛЬ** *м.* — спектакль.

**СПЕКТР** *м. физ.* — спектр (яктылык нурының пыяла призма яки диффракцион рәшәткә аша үтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән төрле төсләр).

**СПЕКТРА'ЛЬНЫЙ** *физ.* — спектраль; *спектральный анализ* — спектраль анализ.

**СПЕКТРО'ГРАФ** *м. физ.* — спектрограф, фотокамералы спектроскоп.

**СПЕКТРО'МЕТР** *м. физ.* — спектрометр, спектр үлчәгеч (яктылык дулкыннарының озынлыгына карап спектраль сызыкларның торышын үлчәү өчен җайланмасы булган спектроскоп).

**СПЕКТРОМЕТРИ'ЧЕСКИЙ** *физ.* — спектрометрия ...-ы; спектрометрик.

**СПЕКТРОМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет, *физ.* — спектрометрия (яктылык дулкыннарының озынлыгын спектрометр ярдәмендә үлчәү).

**СПЕКТРОСКО'П** *м. физ.* — спектроскоп (спектрларны күзәтү приборы).

**СПЕКТРОСКОПИ'ЧЕСКИЙ** *физ.* — спектроскоп ...-ы; спектроскопик.

**СПЕКТРОСКОПИ'Я** *ж. мн.* нет — спектроскопия (спектрларны спектроскоп ярдәмендә тикшерү).

**СПЕКУЛИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. спекуляция ясау, спекуляция белән шөгыльләнү, алып-сату белән шөгыльләнү, спекуляция итү; 2. ...-дан файдаланып спекуляция ясау, ...-дан файдалану; *спекулировать на разнице в ценах* — бәяләрнең төрле булуыннан файдаланып спекуляция ясау; 3. *перен. книж.* ...-дан файдаланып эш итү; *спекулировать на чьих-нибудь затруднениях* — берәр кешенең кыенлыкларыннан (кыен хәлгә төшүеннән) файдаланып эш итү.

**СПЕКУЛЬНУ'ТЬ** *однокр. просторечь. фам.* — спекуляция ясап алу.

**СПЕКУЛЯ'НТ** *м.*, **СПЕКУЛЯ'НТКА** *ж.* — спекулянт.

**СПЕКУЛЯ'НТСКИЙ** — спекулянт ...-ы, спекулянтларча ..., спекулянтларга хас.

**СПЕКУЛЯТИ'ВНЫЙ** I *книж.* — спекуляция ...-ы, спекулятив, спекуляциягә нигезләнгән; *спекулятивные расчёты* — спекуляциягә нигезләнгән расчётлар.

**СПЕКУЛЯТИ'ВНЫЙ** II *филос.* — спекулятив; *спекулятивная философия* — спекулятив философия (тәҗрибәгә таянмыйча, чынбарлыкны алдан билгеләнгән абстракт принциплар буенча гына тикшерә торган идеалистик философия).

**СПЕКУЛЯ'ТОР** *м. старин. церк.* — 1. корал йөртүче; 2. палач, җәллад.

**СПЕКУЛЯ'ЦИЯ** *ж.* — 1. спекуляция, спекуляция ясау; *спекуляция земельными участками* — җир участоклары белән спекуляция ясау; *неудачная спекуляция* — уңышсыз спекуляция; 2. к. спекулировать 3.

**СПЕЛЕНА'ТЬ** *сов.* — биләү, биләп кую.

**СПЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — өлгергәнлек, житлеккәнлек.

**СПЕ'ЛЫЙ** — өлгергән, пешкән, җитлеккән.

**СПЕ'НСЕР** *м. старин.* — спенсер (кыска күртканың бер төре).

**СПЕРВА'** *нареч. разг.* — элек, башта.

**СПЕРВОНАЧА'ЛА**, **СПЕРВОНАЧА'ЛУ** *нареч. просторечь.* — к. сперва.

**СПЕ'РЕДИ** *нареч.* и *предлог с род. п.* — алгы яктан, алдан; алгы якта, алда; *спереди находился палисадник* — алгы якта өйтүрбакча бар иде.

**СПЕРЕ'ТЬ** I *сов. просторечь.* — алып китү, күтәреп алып китү; *сундук тяжёлый, его с места не сопрёшь* — сандык авыр, аны урыныннан күтәреп алып китә алмассың.

**СПЕРЕ'ТЬ** II *сов. просторечь.* — чәлдерү (урлау мәгънәсендә).

**СПЕРЕ'ТЬ** III *сов. просторечь.* — кысу, китереп кысу; *его спёрли со всех сторон* — аны төрле яктан китереп кыстылар. ◇ **Дыхание спёрло** — сулышы кысылды, сулышы тарайды, тыны кысылды.

**СПЕРЕ'ТЬСЯ** *сов. просторечь.* — җыелу, килеп җыелу, килеп тыгылу.

**СПЕ'РМА** *ж. мн.* нет, *биол.* — сперма, мәни (аталык орлыклары).

**СПЕРМАТОЗО'ИД** *м. биол.* — сперматозоид, аталык орлыгы.

**СПЕРМАЦЕ'Т** *м. мн.* нет, *спец.* — спермацет (парфюмериядә, косметикада һәм техникада кулланыла торган ак төстәге майлы масса).

**СПЕРМАЦЕ'ТОВЫЙ** *спец.* — спермацеттан ясалган, спермацетлы; *спермацетовая мазь* — спермацеттан ясалган мазь.

**СПЕРМИ'Й** *м. биол.* — к. сперматозоид.

**СПЕРМИ'Н** *м. мн.* нет, *биол.* — спермин (дару).

**СПЁРТОСТЬ** *ж. мн.* нет — бөркүлек, тынчулык.

**СПЁРТЫЙ** I— чәлдерелгән (урланган мәгънәсендә).

**СПЁРТЫЙ** II—1. кысылган; 2. бөркү, тынчу; *спёртый воздух* — тынчу һава.

**СПЕСИ'ВЕТЬ** *несов. простореч.*— тәкәбберләнә бару, эреләнә бару, борын(ын) күтәрә бару, һавалана бару, кәпрәя бару.

**СПЕСИ'ВЕЦ** *м. устар.*— һавалы кеше, тәкәббер кеше, эре кеше; кәпрәючән кеше, борын күтәрүчән кеше.

**СПЕСИ'ВИТЬСЯ** *несов. разг. устар.*— тәкәбберләнү, эреләнү, борын күтәрү, кәпрәю.

**СПЕСИ'ВИЦА** *ж. устар.*— к. спесивец.

**СПЕСИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. спесь.

**СПЕСИ'ВЫЙ** — һавалы, тәкәббер, эреләнүчән, борын күтәрүчән, кәпрәючән.

**СПЕСЬ** *ж. мн.* нет — һавалылык, тәкәбберлек, эрелек, борын күтәрүчәнлек, кәпрәючәнлек.

**СПЕТЬ** I *сов.*—1. жырлау, жырлап бирү; 2. *(о птицах)* сайрау. ◇ **Песня или песенка спета** *чья* — жыры жырланган, бәйрәме үткән, эше узган.

**СПЕТЬ** II *несов.*—1. өлгерү, өлгереп килү, пешеп килү, житеп килү; пешү, житү; *рожь колосится и спеет* — арыш башакланып өлгереп килә; 2. *обл.* *(поспевать)* өлгерү, житешү, калышмау.

**СПЕ'ТЬСЯ** *сов.*—1. бергә жырларга өйрәнү, бергә жырларга өйрәнеп житү; *хор ещё не спелся* — хор бергә жырларга өйрәнеп житмәгән әле; 2. *перен. простореч. неодобр.* килешү, бер сүзгә килү, уртак тел табу; сер килешү; *с ним ни в какой работе не спеться* — һичбер нинди эштә дә аның белән уртак тел табып булмый.

**СПЕХ** *м. мн.* нет, *разг.*— ашыгычлык, ашыгу. ◇ **На спех** (или **наспех**)— ашыгыч рәвештә. **Не к спеху** *в знач. сказ.*— ашыгыч түгел.

**СПЕЦ** *м. простореч.*— 1. специалист, белгеч; *крупный спец* — зур белгеч; 2. оста, мастер; *он в этом деле спец* — ул бу эшнең остасы.

**СПЕЦ-**... — махсус; *спецотдел* — махсус бүлек.

**СПЕЦИАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — 1. специализация, специальләштерү; 2. к. специализироваться 1.

**СПЕЦИАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— специальләштерү.

**СПЕЦИАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов.* специальләшү; белгечлек итеп алу; *специализироваться по радиотехнике* — радиотехника буенча специальләшү; 2. *страд.* специальләштерелү.

**СПЕЦИАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж. неодобр.*— специализация белән кирәгеннән артык мавыгу.

**СПЕЦИАЛИ'СТ** *м.*, **СПЕЦИАЛИ'СТКА** *ж.*— специалист, белгеч.

**СПЕЦИА'ЛЬНО** *нареч.*— 1.махсус (рәвештә), специаль рәвештә; *специально приготовленный прибор* — махсус әзерләнгән прибор; 2. генә, махсус; *я пришёл специально для того, чтобы поговорить с вами* — мин сезнең белән сөйләшер өчен махсус килдем. ◇ **Выражаться слишком специально** — чамадан тыш специаль терминнар куллану.

**СПЕЦИА'ЛЬНОСТЬ** *ж.*—1. *только ед. редко* специальлек, специаль булу; *специальность термина* — терминның специаль булуы; 2. белгечлек, специальность (а. фән, техника, сәнгатьнең аерым бер тармагы; *он избрал своей специальностью радиотехнику* — ул үзенең специальносте итеп радиотехниканы алды; б. профессия, төп квалификация; *он по специальности бухгалтер* — ул үзенең специальносте буенча бухгалтер); 3. бар эше, бар яратканы; *насмешки над товарищами были его специальностью* — аның бар яратканы иптәшләреннән көлү иде.

**СПЕЦИА'ЛЬНЫЙ** — махсус, специаль; *специальный корреспондент газеты* — газетаның махсус хәбәрчесе.

**СПЕЦИ'ФИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— специфика, специфик үзенчәлек, үзенчәлек.

**СПЕЦИФИКА'ТОР** *м. спец.*— спецификатор, спецификацияләүче.

**СПЕЦИФИКА'ЦИЯ** *ж.*—1. *только ед. (действие)* к. специфицировать; 2. *тех. торг.* спецификация (а. житештерелгән әйбернең, мәсәләнң, механизмның, машинаның һ. б., специфик үзенчәлекләрен күрсәтә һәм аның үзкыйммәтен яки бәясен билгеләү өчен хезмәт итә торган документ; б. житештерелә яки заказ бирелә торган әйбернең специфик үзенчәлекләре язылган документ).

**СПЕЦИ'ФИКУМ** *м. мн.* нет, *книж.*— к. специфика.

**СПЕЦИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— спецификацияләштерү, специфик үзенчәлекләрен билгеләү, специфик үзенчәлекләрен күрсәтү.

**СПЕЦИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— спецификацияләштерү, специфик үзенчәлекләре билгеләнү, специфик үзенчәлекләре күрсәтелү.

**СПЕЦИФИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— специфик, үзенә генә хас (булган).

**СПЕЦИФИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— спецификлык, үзенә генә хас булу.

**СПЕЦИФИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. специфический.

**СПЕ'ЦИЯ** *ж. чаще мн.*—1. дару үләннәре; 2. ашка сала торган үләннәр.

**СПЕЦО'ВКА** *ж. разг.*— спецовка, махсус эш киеме (предприятиедә эшләгәндә кия торган).

**СПЕЦОДЕ'ЖДА** *ж. мн.* нет — к. спецовка.

**СПЕЧЬ** *сов. простореч.*— пешерү, пешереп алу (икмәк, бәлеш кебек ашамлыклар турында).

**СПЕ'ЧЬСЯ** *сов.*—1. пешү, пешеп житү, пешеп чыгу; *блины спеклись* — белен пеште; 2. укмашу, оешу; *кровь спеклась сгустками* — кан төер-төер булып укмашкан; 3. *тех.* эреп укмашу; *руда спеклась* — руда эреп укмашкан.

**СПЕ'ШИВАТЬ** *несов.*— к. спешить.
**СПЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. спешиться; **2.** *страд.* аттан төшерелү, аттан төшереп җәяүлегә калдырылу.
**СПЕ'ШИТЬ** *сов.*— аттан төшерү, аттан төшереп җәяүлегә калдыру.
**СПЕШИ'ТЬ** *несов.*— ашыгу; *он вечно спешит* — ул гомер буе ашыга. ◇ **Часы спешат** — сәгать алга китә. **Не спеша** — ашыкмыйча гына, акрын гына.
**СПЕ'ШИТЬСЯ** *сов.*— аттан төшү.
**СПЕ'ШКА** *ж. мн.* нет — ашыгу.
**СПЕ'ШНО** *нареч.*— ашыгыч, ашыгыч рәвештә, ашыгып, ашык-пошык.
**СПЕ'ШНОСТЬ** *ж. мн.* нет —**1.** ашыгычлык; **2.** ашыгыч хәл.
**СПЕ'ШНЫЙ** — ашыгыч. ◇ **В спешном порядке** — ашыгыч рәвештә.
**СПИВА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. спить.
**СПИВА'ТЬСЯ** *несов. простореч.*— к. спиться.
**СПИДО'МЕТР** *м. спец.* — спидометр (автомобильнең, мотоциклның йөрү тизлеген һәм күпме юл үткәнен күрсәтә торган прибор).
**СПИ'КЕР** *м. полит.*— спикер (Англиядә общиналар палатасы председателе).
**СПИ'ЛИВАТЬ** *несов.*— к. спилить.
**СПИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— пычкы белән киселү, пычкы белән кисеп алыну, пычкы белән кисеп ташлану.
**СПИЛИ'ТЬ** *сов.*— **1.** пычкы белән кисү, пычкы белән кисеп алу, пычкы белән кисеп ташлау; *спилить сосну* — наратны пычкы белән кисү; **2.** *спец.* игәү белән шомарту, игәүләү.
**СПИНА'** *ж.*—**1.** арка; *выпрямить спину* — арканы турайту; **2.** арт; *ветер в спину* — җил арттан исә; *вдруг послышались шаги за спиной* — кинәт минем артымда аяк тавышлары ишетелде. ◇ **Выезжать на** *чьей* **спине** *разг.* — кешедән файдалану, кеше көченнән файдалану. **Ездить на** *чьей* **спине** — кеше җилкәсенә атлану, кеше җилкәсенә атланып алу. **За спиной у** *кого* (делать что-нибудь) *разг. ирон.*— үзе югында эшләү, артында эшләү, яшереп эшләү. **На собственной спине** (испытать, узнать) — үз җилкәңдә (тату), үз башыңнан (кичерү). **Нож в спину** *ритор.*— арттан пычак кадау (хыянәт итү).
**СПИ'НКА** *ж.*—**1.** к. спина; **2.** арт; *спинка стула* — урындыкның арты; **3.** *порт.* арка, күлмәкнең арка өлеше.
**СПИ'ННИНГ** *м. мн.* нет — спиннинг (**1.** әйләнеп тора торган ялтыравык-блесна ярдәмендә балык тоту ысулы; **2.** шундый ялтыравык-блесна үзе).
**СПИННО'Й** — арка...-ы, сырт...-ы; *спинной хребет* — арка сөяге (умырткалык).
**СПИРА'ЛЬ** *ж.*— спираль (нокта яки күчәр тирәсендә берничә әйләнеш ясаган винтсыман кәкре сызык һәм шундый пружина).
**СПИРА'ЛЬКА** *ж. тех.*— спиралька, спираль тимер чыбык.
**СПИРА'ЛЬНЫЙ** — спираль..., спиральсыман, спиральгә охшашлы, борма-борма; *спиральная лестница* — спираль баскыч.
**СПИРА'НТ** *м. лингв.*— к. фрикативный.
**СПИРА'ТЬ** I *несов. простореч. вульг.*— к. спереть II.
**СПИРА'ТЬ** II *несов. простореч.*— к. спереть III.
**СПИРА'ТЬСЯ** I *несов. страд. простореч.*— чәлдерелү (урлану мәгънәсендә).
**СПИРА'ТЬСЯ** II *несов. страд. простореч.*— кысылу, китереп кысылу.
**СПИРА'ТЬСЯ** III *несов. простореч.*— к. спереться.
**СПИРИ'Т** *м.*— спирит, спиритизмга ышанучы.
**СПИРИТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — спиритизм (үлгән кешеләрнең рухлары белән бәйләнештә булырга мөмкин дигән мистик караш).
**СПИРИТИ'ЧЕСКИЙ** — спиритик, спиритизм...-ы; *спиритический сеанс* — спиритизм сеансы.
**СПИРИ'ТКА** *ж.*— к. спирит.
**СПИРИТУАЛИ'ЗМ** *м. филос.*— спиритуализм (философиядә рухны реаль нәрсә дип таныган, материянең реальлеген инкарь итә торган идеалистик юнәлеш).
**СПИРИТУАЛИ'СТ** *м. филос.*— спиритуалист, спиритуализм яклы кеше, спиритуализм тарафдары.
**СПИРИТУАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *филос.*— спиритуализм...-ы, спиритуалистик.
**СПИРО'МЕТР** *м. мед.*— спирометр (үпкәнең һава сыйдырышын үлчи торган прибор).
**СПИРОХЕ'ТА** *ж. бакт.*— спирохета (бактерия).
**СПИРТ** *м.*— спирт.
**СПИРТНО'Е** *ср. мн.* нет, *в знач. сущ.*— спиртлы эчемлек, исерткеч эчемлек.
**СТА'ВИТЬ** *несов.* — **1.** кую; *ставить палку в угол* — таякны почмакка кую; 2. бастыру; *ставить в строй* — сафка бастыру; 3. утырту; *ставить столбы* — баганалар утырту; 4. кую, кертү; *ставить телефон* — телефон кую; **5.** *воен.* кую, урнаштыру; *ставить полк на новые квартиры* — полкны яңа квартирларга урнаштыру; 6. оештыру; *на заводе ставят производство новых деталей* — заводта яңа детальләр эшләп чыгаруны оештыралар; 7. калдыру; *ставить в неловкое положение* — уңайсыз хәлдә калдыру; 8. *торг. спец.* җибәреп (биреп) тору; *ставить дрова на фабрику* — фабрикага утын биреп тору; 9. *простореч.* бәя кую, бәя бирү, бәяләү; *ставить вещь в 100 рублей* — әйберне 100 сумга бәяләү; *его ставят высоко* — аны югары бәялиләр. ◇ **Ставить паруса** — җилкән күтәрү. **Ставить в вину** — гаепләү, гаеп санау. **Ставить в известность** — хәбәр итү. **Ставить в связь** — бәйләү. **Ставить в обязанность** — бурыч итеп кую, йөкләү. **Ставить в упрёк** — битәрләү, шелтәләү. **Ставить подножку** — аяк чалу. **Ставить за правило** — кагыйдә итеп алу. **Его ни во что не ставят** — аның белән исәпләшмиләр, аны бер тиенгә дә куймыйлар. **Ставить во главу угла** — иң төп (иң әһәмиятле) мәсьәлә итеп кую. **Ставить** (**поставить**) **крест** — **к.** крест. **Ставить на вид** — кисәтү. **Ставить на карту** — к. карта. **Ставить на ноги** — к. нога. **Ставить на одну доску** — к. доска. **Ставить** (настаивать, поставить) **на своём** — үзенекен итү, теләгенә ирешү. **Ставить точки над и** — к. точка. **Ставить часы** — сәгатьне дөресләү. **Ставить** *кого-н.* **на колени** — тезләндерү. **Ставить пиявки** — сөлек салу. **Ставить избу** — йорт салу, йорт кую.

**СТА'ВИТЬСЯ** *несов. страд.* — куелу.

**СТА'ВКА** I *ж.* — ставка (1. гаскәр башлыгының урнашкан урыны; 2. штаб, башквартира). ◇ **Очная ставка** — к. очный.

**СТА'ВКА** II *ж.* — 1. (*в азартных играх*) уенда куелган акча; 2. *перен.* исәп тоту, таяну; *нельзя делать ставку на слабость врага* — дошманның көчсезлегенә исәп тотарга ярамый; 3. эш хакы; *повышение ставок шахтёров* — шахтёрларның эш хакларын арттыру; 4. *фин.* норма; *ставки налога* — налог нормалары.

**СТА'ВЛЕННИК** *м.*, **СТА'ВЛЕННИЦА** *ж.* —1. *старин.* кандидат; 2. куелган кеше, куйган кеше (аерым яки бер төркем кешеләрнең теләге буенча яки тырышлыгы белән алар файдасын күзәтү өчен куелган кеше); *он — ставленник самого директора* — ул — директор үзе куйган кеше.

**СТАВНО'Й** *спец.* — бер урынга куелган, бер урында тора торган, бер урынга куела торган.

**СТА'ВНЯ** *ж.* — тәрәзә капкачы.

**СТАВО'К** *м. обл.* — буа, бөя.

**СТАГНАЦИО'ННЫЙ** *экон.* — стагнация ...-ы, стагнацион; *стагнационные явления* — стагнацион күренешләр.

**СТАГНА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *экон.* — стагнация, торгынлык.

**СТАДИА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *науч.* — стадиальлек.

**СТАДИА'ЛЬНЫЙ** *науч.* — стадиаль.

**СТА'ДИЙ** *м. истор.* — стадий (борынгы грекларда — 150—190 метрлар чамасында булган озынлык үлчәве берәмлеге).

**СТАДИ'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *науч.* — к. стадиальность.

**СТАДИ'ЙНЫЙ** *науч.* — к. стадиальный.

**СТАДИО'Н** *м.* — стадион (физкультура бәйрәмнәре, спорт ярышлары үткәрә торган мәйданы булган корылма).

**СТА'ДИЯ** *ж.* — 1. стадия, чор; *стадия расцвета* — чәчәк ату чоры; 2. *истор.* стадия (борынгы грекларда — стадион); 3. *истор.* к. стадий.

**СТА'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — көтү (өер) булып яшәү.

**СТА'ДНЫЙ** — 1. көтү (өер) булып яши торган, көтү (өер) булып яшәүче; *стадные животные* — көтү (өер) булып яшәүче хайваннар; 2. көтү (өер) булып яшәү ...-ы; *стадный инстинкт* — көтү (өер) булып яшәү инстинкты.

**СТА'ДО** *ср.* — 1. көтү; өер; *стадо коров* — сыер көтүе; 2. *только ед. эк.* (терлек) саны; *за последние годы резко увеличилось стадо крупного рогатого скота* — соңгы еллар эчендә эре мөгезле терлекләр саны бик нык артты; 3. *перен. разг. пренебр.* өер, көтү. ◇ **Панургово стадо** *книж.* — сарык көтүе (аңсыз рәвештә үзенең юлбашчысына буйсынучан төркем, толпа).

**СТАЖ** *м. мн.* нет — стаж (1. берәр өлкәдә эшләү яки хезмәт итү срогы; 2. эшкә яңа гына урнашкан кешеләргә үз белгечлеге буенча практик тәҗрибә алу өчен бирелгән срок).

**СТАЖЁР** *м.*, **СТАЖЁРКА** *ж.* — стажёр, сынау стажы үтүче.

**СТАЖИ'РОВАТЬ** *несов.* — сынау стажы үтү, стажировка үтү.

**СТАЖИРО'ВКА** *ж. мн.* нет — стажировка, сынау стажы үтү.

**СТАЖИ'СТ** *м.*, **СТАЖИ'СТКА** *ж.* — к. стажёр.

**СТАЗ** *м. мед.* — стаз (күбесенчә кан йөрешенең тукталуы турында).

**СТА'ЗА** *м. биол.* — стаза (кырмыска, бал корты кебек тереклек иясләре бергәлегендә махсус функция үтәүче төркем).

**СТА'ИВАТЬ** *несов.* — к. стаять.

**СТА'ЙЕР** *м. спорт.* — стайер (ерак дистанциягә йөгерүче спортсмен).

**СТА'ЙЕРСКИЙ** *спорт.* — стайер ...-ы; *стайерская дистанция* — стайер дистанциясе.

**СТА'ЙКА** *ж. разг.* — к. стая.

**СТА'ЙНЫЙ** *спец.* — төркем-төркем яшәүче, өер булып яшәүче, өер-өер яшәүче; *стайные птицы* — төркем-төркем яшәүче кошлар.

**СТАКА'Н** *м.* — 1. стакан; 2. *воен.* гильза (снаряд гильзасы). ◇ **Буря в стакане воды** — бер дә юкка чәпчү (юк өчен, бактөяк өчен дулау).

**СТАКА'ННЫЙ** — стакан ...-ы, стакан эшләп чыгару ...-ы; *стаканное производство* — стакан производствосы.

**СТАККА'ТО** *нареч. муз.* — стаккато, өзеп-өзеп.

**СТА'ККЕР** *м. тех.* — стаккер (заводларда авыр йөкләр күтәрү механизмы).

**СТАКНУ'ТЬСЯ** *сов. простореч. неодобр.* — яшерен сүз куешу, сүз беркетеп кую, бер сүзгә килү.

**СТА'КСЕЛЬ** *м. мор.* — стаксель (өчпочмаклы җилкәннең бер төре).

**СТАЛАГМИ'Т** *м. мин.* — сталагмит (тау куышы төбендә түшәмнән төшкән тамчылардан барлыкка килгән известь утырмасы).

**СТАЛАГМИ'ТОВЫЙ** *мин.* — сталагмит ... -ы; сталагмитлы; *сталагмитовая пещера* — сталагмитлы тау куышы. ◇ **Сталагмитовые образования в пещерах** — тау куышларында барлыкка килгән сталагмитлар.

**СТАЛАКТИ'Т** *м. мин.* — сталактит (тау куышы түшәмендә известьлы су тамчылары сарку нәтиҗәсендә барлыкка килгән утырма).

**СТАЛАКТИ'ТОВЫЙ** *мин.* — сталактит ... -ы, сталактитлы; *сталактитовая пещера* — сталактитлы тау куышы.

**СТАЛЕБЕТО'Н** *м. мн.* нет, *тех.* — корычбетон (цементка югары сортлы металл китекләре кушып ясалган төзү материалы).

**СТАЛЕБЕТО'ННЫЙ** *тех.* — корыч-бетон...; *сталебетонные конструкции в сооружениях* — корылмаларда(гы) корыч-бетон конструкцияләр.

**СТАЛЕВА'Р** *м. спец.* — сталевар, корыч эретүче (эшче).

**СТАЛЕДЕ'ЛАТЕЛЬНЫЙ** *тех.*— к. сталелитейный.

**СТАЛЕЛИТЕ'ЙНЫЙ** *тех.*— корыч кою...-ы; *сталелитейный завод* — корыч кою заводы.

**СТАЛЕЛИТЕ'ЙЩИК** *м. спец.*— корыч коючы (эшче).

**СТАЛЕПЛАВИ'ЛЬНЫЙ** *тех.*— корыч эретү ... -ы; *сталеплавильный цех* — корыч эретү цехы.

**СТАЛЕПЛАВИ'ЛЬЩИК** *м. спец.*— корыч эретүче (эшче).

**СТАЛЕПРО'ВОЛОЧНЫЙ** *тех.*— корыч тимер чыбык эшләп чыгара торган, корыч тимер чыбык ... -ы; *сталепроволочный завод* — корыч тимер чыбык эшләп чыгара торган завод.

**СТАЛЕПРОКА'ТНЫЙ** *тех.*— корыч прокатлау ... -ы; *сталепрокатный цех* — корыч прокатлау цехы.

**СТАЛЕПРОКА'ТЧИК** *м. спец.*— корыч прокатлау производствосы эшчесе.

**СТАЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.*— корыч йөгертү, корыч белән каплату (электролиз ярдәмендә).

**СТАЛИ'РОВАТЬСЯ** *тех.*— 1. *сов.* и *несов.* корыч белән каплану; 2. *несов. страд.* корыч йөгертелү, корыч белән каплану.

**СТА'ЛКИВАТЬ** *несов.*— к. столкнуть, столкать.

**СТА'ЛКИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. столкнуться; 2. *страд.* этеп төшерелү.

**СТА'ЛО, СТА'ЛО БЫТЬ** *ввод. сл.*— димәк, шулай булгач.

**СТАЛЬ** *ж.*— корыч.

**СТАЛЬНО'Й** — 1. корыч..., корычтан ясалган; *стальной нож* — корыч пычак; 2. корыч ... -ы; корыч эшләп чыгара торган; *стальной трест* — корыч тресты; 3. корычсыман, ачык соры; *стальной цвет* — ачык соры төс; 4. *перен.* корыч..., корычтай ...; корыч кебек таза (нык); *стальные нервы* — корыч кебек таза нервлар; *стальные мышцы* — корыч кебек нык мускуллар.

**СТАМЕ'СКА** *ж.*— өтерге.

**СТАМЕ'СОЧНЫЙ** — өтерге ... -ы; *стамесочная рукоятка* — өтерге сабы.

**СТАМУ'ХА** *ж. обл. спец.*— сайлыкка утырган боз тавы (торос).

**СТАН** I *м.*— 1. (*туловище*) сын, гәүдә, буй; 2. *обл.* буй; *стан рубахи* — күлмәк буе.

**СТАН** II *м.*— 1. стан (а. гаскәр урнашкан урын, лагерь; б. ерак кырларда эшләгәндә колхозчылар урнашкан урын; *полевой колхозный стан* — колхозчыларның кыр станы; в. *перен.* сугышучы як; г. *перен. книж.* көрәшүче як, иҗтимагый-политик төркем; д. *дореволь.* өязнең административ-полицейский бүлекчесе); 2. *старин.* к станок I в 1 знач.

**СТАН** III *м.*— стан (1. *тех.* рельс, труба һ. б. ш. эре металл әйберләр эшләп чыгара торган зур катлаулы машина, зур станок; 2. *тех. обл.* киндер сугу станогы; 3. *обл.* берәр нәрсәнең тулы комплекты, мәсәлән, бер арбалык тәгәрмәч яки бер ат дагалары дага һ. б.; 4. *обл.* умарта куя торган казыклар).

**СТАНД** *м. тех. спец.*— к. стенд.

**СТАНДА'РТ** I *м.*— 1. стандарт, үрнәк; *изготовлять что-н. по определённому стандарту* — берәр нәрсәне билгеле бер стандарт (үрнәк) буенча хәзерләү; 2. *перен. разг. неодобр. (шаблон)* стандарт, калып, шаблон, бер үк төрле нәрсә; 3. *эк. (мерило)* стандарт, үлчәгеч.

**СТАНДА'РТ** II *м.*— к. штандарт.

**СТАНДАРТИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *тех. эк.*— стандартлаштыру, стандартлаштырылу, бер стандартка салу, стандартизация (1. күп төрдә чыгарыла торган әйберләрнең төрләрен кимету юлы белән производствоны рационаллаштыру; 2. эш ысулларын бертөрле нормага салу).

**СТАНДАРТИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— стандартлаштыру, бер стандартка салу.

**СТАНДАРТИЗИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов.* стандартлашу; 2. *несов. страд.* стандартлаштырылу, бер стандартка салыну.

**СТАНДАРТИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— к. стандартизировать.

**СТАНДАРТИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.*— к. стандартизироваться.

**СТАНДА'РТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — стандартлык.

**СТАНДА'РТНЫЙ** — 1. стандарт..., стандартлы, бер үк үрнәк буенча эшләнгән; *стандартная мебель* — стандарт мебель; 2. *перен. разг. неодобр.* стандарт..., шаблон..., трафарет..., бер үк төрле; *стандартные слова* — стандарт сүзләр.

**СТА'НДЕР** *м. тех.*— к. стендер.

**СТАНИ'НА** *ж.*— 1. *тех.* станина, төп, нигез (машинаның, станокның кузгалмый торган өлеше, нигез өлеше); *чугунная станина станка* — станокның чуен нигезе (станинасы); 2. к. станок II во 2 знач.

**СТАНИО'ЛЕВЫЙ** *тех.*— станиоль...; *станиолевая обвёртка* — станиоль төргеч.

**СТАНИО'ЛЬ** *м. мн.* нет, *тех.*— станиоль, кургаш, фольга; кургаш кәгазь.

**СТАНИ'ЦА** *ж.*— 1. станица (казакларда зур авыл); *донские станицы* — Дон буе станицалары; 2. *устар., поэт.* к. стая.

**СТАНИ'ЧНИК** *м.*— 1. станицада яшәүче казак, станица казагы; 2. *старин.* кыю егет; юлбасар.

**СТАНИ'ЧНЫЙ** — станица ... -ы; *станичный совет* — станица советы.

**СТАНКОВЩИ'К** *м. спец.*— к. станочник.

**СТАНКО'ВЫЙ** I *старин., обл.*— станоктагы, станокта тора торган; *станковые кони* — станокта тора торган атлар.

**СТАНКО'ВЫЙ** II — станоклы; *станковый пулемёт* — станоклы пулемёт.

**СТАНКОСТРОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — станоклар төзү, станоклар эшләп чыгару.

**СТАНКОСТРОИ'ТЕЛЬ** *м. спец.*— станоклар төзүче, станоклар эшләп чыгаручы.

**СТАНКОСТРОИ'ТЕЛЬНЫЙ** — станоклар төзү ... -ы, станоклар ясау ... -ы; *станкостроительные заводы* — станоклар төзү заводлары.

**СТАНОВА'ТЬ** *несов. обл.*— туктау, лагерь булып урнашу.

**СТАНОВИ'ТЬ** *несов. простореч. обл.*— к. ставить.

**СТАНОВИ'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. стать I в 1, 2, 4, 5, 10 *знач.*; **2.** *филос.* үсү; **3.** *разг.* к. ставиться.

**СТАНОВИ'ЩЕ** *ср.*— становище (вакытлы тору урыны).

**СТАНОВЛЕ'НИЕ** *ср. филос.*— (хәрәкәт һәм алга бару процессында) үсү, формалашу.

**СТАНОВО'Й** — **1.** *обл.* төп, нигез, үзәк; *становой берег* — төп яр; *становой водораздел* — төп субүләр; *г. обл.* арка ... -ы; *становая жила* — арка сеңере. ◇ **Становой** или **становой пристав** *доревол.*— становой (полиция чиновнигы, стан полициясе башлыгы). **Становой хребет** *перен.*— үзәк, төп нәрсә, мөһим нәрсә. **Становой якорь** *обл. спец.*— судно туктаганда салына торган зур якорь.

**СТАНОВЩИ'К** *м.*— **1.** *обл.* становищеда торучы; **2.** *старин.* почта станциясе башлыгы, ямчылар станциясе башлыгы.

**СТАНО'ВЬЕ** *ср. обл.*— к. становище.

**СТАНО'К** I *м.*— станок (**1.** *старин. обл.* почта станциясе, ямчылар станциясе; **2.** Себерд кечкенә пучинкә; **3.** *обл.* к. становище; **4.** *спец. воен.* абзарда бер ат өчен бүлеп куйган урын; **5.** *спец.* ат дагалау станы).

**СТАНО'К** II *м.*— **1.** станок; *ткацкий станок* — туку станогы; **2.** *воен.* станок, лафет; *пулемётный станок* — пулемёт станогы; **3.** *спец.* арба станы.

**СТАНО'ЧНИК** *м.*, **СТАНО'ЧНИЦА** *ж.*— станокчы, станокта эшләүче (эшче).

**СТАНО'ЧНЫЙ** — станок ... -ы, станоклар ... -ы; *станочный парк завода* — заводның станоклар паркы.

**СТАНС** *м. лит.*— станс (**1.** шигырьләрдә — төгәл бер синтаксик тезем булып тора торган строфа; **2.** *только мн.* шундый строфалардан торган шигырь).

**СТАНЦИО'ННЫЙ** — станция ... -ы; *станционный зал* — станция залы.

**СТА'НЦИЯ** *ж.*— станция (**1.** тимер юлда һәм башка аралашу юлларында туктау урыны, туктау пункты; **2.** *разг.* шундый ике пункт арасы; **3.** кайбер учреждение, предприятие яки махсус фәнни-тикшеренү учреждениеләренең атамасы).

**СТА'ПЕЛЬ** *м.*— стапель (**1.** *мор.* судно корпусларын җыю һәм судноларны суга төшерү өчен хезмәт итә торган урын; **2.** *тех.* самолёт җыю урыны).

**СТА'ПЛИВАТЬ** *несов.*— к. стопить 1.

**СТА'ПЛИВАТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. стопиться 1; **2.** *страд.* кушып эретелү; эретелү.

**СТА'ПТЫВАТЬ** *несов.*— к. стоптать.

**СТА'ПТЫВАТЬСЯ** *несов.*— **1.** к. стоптаться; **2.** *страд.* кия-кия чалышайтылу (аяк киеме турында).

**СТАРА'НИЕ** *ср.*— тырышлык, тырышу, иҗтиһат.

**СТАРА'ТЕЛЬ** *м. спец.*— старатель (алтын эзләүче ялгызак эшче).

**СТАРА'ТЕЛЬНО** *нареч.*— тырышып, тырышлык белән.

**СТАРА'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тырышлык.

**СТАРА'ТЕЛЬНЫЙ** — **1.** тырыш, тырышучан; *старательный рабочий* — тырыш эшче; **2.** тырышып эшләнгән, тырышлык белән башкарылган; *старательная работа* — тырышлык белән башкарылган эш.

**СТАРА'ТЕЛЬСКИЙ** *спец.*— старатель...-ы, старательләр ... -ы; старательлек ... -ы; *старательская артель* — старательләр артеле; *старательские работы* — старательлек эшләре.

**СТАРА'ТЕЛЬСТВО** *ср. спец.*— старательлек, старательләр промыселы.

**СТАРА'ТЬСЯ** *несов.*— тырышу.

**СТА'РБОРД** *м. мор.*— к. штирборт.

**СТА'РЕ** *нареч. поэт. устар.*— картрак, олырак; искерәк.

**СТАРЕ'ЙШИНА** *м. истор. этногр.*— старейшина, аксакал, ыру башлыгы. ◇ **Совет старейшин** — старейшиналар советы (төрле оешмаларда аерым органнар атамасы, мәсәлән, делегация җитәкчеләре советы, фракция лидерлары советы һ. б.).

**СТАРЕ'ЙШИНСТВО** *ср. мн.* нет, *истор., этногр.*— старейшиналык, старейшина вазифасы, аксакал вазифасы.

**СТАРЕ'ТЬ** *несов.*— **1.** картаю; **2.** искерү; *моды всегда стареют* — модалар һәрвакыт искерәләр.

**СТАРЕ'ТЬСЯ** *несов.*— к. стареть 1.

**СТА'РЕЦ** *м.*— **1.** *книж. ритор.* к. старик; **2.** *церк.* карт монах; **3.** *обл.* хәерче (сукыр) карт.

**СТАРИ'К** *м.*— карт, карт кеше.

**СТАРИКА'Н** *м. разг. фам.*— картлач.

**СТАРИКА'ШКА** *м. уничижит. разг. фам.*— картлач.

**СТАРИКО'ВСКИЙ** *разг.*— карт(лар) ... -ы, карт кеше(ләр) ... -ы; *стариковские привычки* — карт кеше гадәтләре.

**СТАРИНА'** I *ж.*— **1.** борын заман; *в старину* — борын заманда; **2.** борынгылык; борынгы гореф-гадәтләр; *в деревне мало осталось старины* — авылда борынгылык аз калды. ◇ **По старине** — борынгы гадәтләр буенча, элеккечә. **Тряхнуть стариной** *разг.*— борынгыны искә төшерү, яшьлекне (яшь чакны) искә төшерү.

**СТАРИНА'** II *м. разг. фам.*— карт (кеше), картлач.

**СТАРИНА'** III *ж. лит.*— былина (легендар батырлар турында рус халык эпосы).

**СТАРИ'НКА** *ж.*: **по старинке** *преимущ. неодобр.*— борынгыча, искечә, борынгы (иске) гадәт буенча; *работать по старинке* — искечә эшләү; *держаться старинки* — искечә эш итү, иске гадәт буенча эш итү.

**СТАРИ'ННЫЙ** — **1.** борынгы; *старинный обычай* — борынгы гадәт; *старинная пословица* — борынгы мәкаль; **2.** борынгы, элеккеге, иске; *старинный друг* — иске дус; **3.** иске, искергән; *старинный метод* — искергән метод.

**СТАРИ'НЩИК** *м. устар.*— антиквар (борынгы әйберләр һәвәскәре һәм аларны җыючы кеше).

**СТА'РИТЬ** *несов.*— картайту, картайтып күрсәтү.

**СТА'РИТЬСЯ** *несов.*— 1. картаю; *он быстро старится* — ул бик тиз картая; 2. *разг.* карт булып күренергә тырышу, үзен карт итеп күрсәтү, яшен арттыру; *зачем ты старишься? это тебе нейдёт* — нигә син карт булып күренергә тырышасың? бу сиңа килешми.

**СТА'РИЦА** *ж. обл.*— иске үзән, иске юл (елганың).

**СТАРИЧИ'НА** *м. мн.* нет, *разг.*— к. старик.

**СТАРИЧО'К** *м.*— к. старик.

**СТАРИЧЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир. простореч. пренебр.*— картлар, җыен карт-коры, карт-корылар.

**СТА'РКА** *ж. мн.* нет — старка (озак торылган аракының бер төре).

**СТАРНОВА'ТЬ, СТАРНО'ВКА** — к. сторновать, сторновка.

**СТАРОБЫ'ТНЫЙ** *книж. устар.*— бик күптәнге, борынгы, бик иске.

**СТАРОВЕ'Р** *м.*, **СТАРОВЕ'РКА** *ж. разг.*— 1. старовер (христиан динендә староверлыкны яклаучы кеше); 2. *перен. шутл.* иске карашлы кеше, иске гадәтләр буенча эш итүче кеше.

**СТАРОВЕ'РЧЕСКИЙ** *устар.*— староверлар ...-ы, староверлык ...-ы; *староверческое кладбище* — староверлар зираты.

**СТАРОВЕ'РЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.*— староверлык (рус христианнары арасында XVII йөздә раскол нәтиҗәсендә барлыкка килеп, берничә дини мәзһәпне берләштергән, диндәге һәм тормыштагы иске тәртипләрне яклаган дини агым).

**СТАРОВЕ'РЩИНА** *ж. мн.* нет, *собир. разг. устар.*— староверлар.

**СТАРОДА'ВНИЙ** — күптән үткән, күптән узган (булган), борынгы, бик күптәнге.

**СТАРОДА'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— борынгылык, бик күптән булу, бик күптәнге булу.

**СТАРОДУ'БКА** *ж. обл.*— кайбер болын һәм кыр чәчәкләренең исеме (мәсәлән, үтчәчәкне, казаякны шулай атыйлар).

**СТАРОЖИ'Л** *м.*, **СТАРОЖИ'ЛКА** *ж.*— (бер урында) күптән яшәүче кеше, күп еллар(дан бирле) торучы кеше.

**СТАРОЖИ'ЛЫЙ, СТАРОЖИ'ЛЬЧЕСКИЙ** *книж.*— (бер урында) күптәннән бирле яшәүче, күп еллар(дан бирле) торучы.

**СТАРОЗАВЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— борынгылык, иске карашлылык; искелек.

**СТАРОЗАВЕ'ТНЫЙ** — 1. борынгы карашлы, иске карашлы; *старозаветный человек* — иске карашлы кеше; 2. *неодобр.* борынгыдан килгән, иске, искедән саклanып килгән; *старозаветные взгляды* — иске карашлар.

**СТАРОЗАПА'ШНЫЙ** *обл. с.-х.*— к. старопахотный.

**СТАРОМО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — иске мода белән тегелгәнлек, иске мода буенча тегелгәнлек, искечә тегелгәнлек.

**СТАРОМО'ДНЫЙ** — 1. иске модадагы, модадан чыккан, иске мода белән ...-ган, иске мода буенча ...-ган; *старомодный фрак* — иске мода буенча тегелгән фрак; 2. *перен. разг. неодобр.* иске, искергән; *старомодный метод* — искергән метод; 3. *перен. разг. неодобр.* иске карашлы; *старомодный человек* — иске карашлы кеше.

**СТАРООБРА'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — карт чырайлылык; картлык; *старообразность лица* — чырайның картлыгы.

**СТАРООБРА'ЗНЫЙ** — карт чырайлы; карт; карт кеше төсле, картларсыман, картларча...; *старообразное лицо* — карт чырай; *старообразная улыбка* — карт кеше төсле елмаю, картларсыман елмаю.

**СТАРООБРЯ'Д** *м. разг. устар*— к. старообрядец.

**СТАРООБРЯ'ДЕЦ** *м.*, **СТАРООБРЯ'ДКА** *ж.*— к. старовер.

**СТАРООБРЯ'ДЧЕСКИЙ** — к. староверческий.

**СТАРООБРЯ'ДЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *церк.*— к. староверчество.

**СТАРОПА'ХОТНЫЙ** *обл. с.-х.*— күп еллар буе сөрелеп килгән, күптән сөрелеп килгән; *старопахотные земли* — күптән сөрелеп килгән җирләр.

**СТАРОПА'ШНЯ** *ж. обл.*— иске басу (күп еллар буена сөрелеп килә торган җир).

**СТАРОПЕЧА'ТНЫЙ** *филол. спец.*— борынгы басма (дини китапларны XVII йөзнең икенче яртысында үткәрелгән төзәтүгә кадәр яки XVIII йөзнең башына кадәр басылган); *старопечатные книги* — борынгы басма китаплар.

**СТАРОРЕЖИ'МЕЦ, СТАРОРЕЖИ'МЩИК** *м.*— иске режимчы, иске режим кешесе, иске режимны яклаучы кеше, иске тәртипне саклаучы (патша заманыннан калган иске карашларны яклаучы кеше).

**СТАРОРЕЖИ'МНОСТЬ** *ж. мн.* нет — иске режимга хас булу, иске режимдагыча булу, иске режимлылык; *старорежимность взглядов* — карашларның иске режимдагыча булуы.

**СТАРОРЕЖИ'МНЫЙ** — 1. иске режим ...-ы; революциягә кадәр булган; *старорежимные времена* — иске режим заманы; 2. иске режимга хас, патша заманыннан калган; *старорежимные взгляды* — патша заманыннан калган карашлар.

**СТАРОРЕ'ЧЬЕ** *ср. обл.*— коры елга, кипкән үзән.

**СТАРОСВЕ'ТСКИЙ** *книж. устар.*— борынгы, иске заман ...-ы, искечә яшәүче, борынгыча яшәүче.

**СТАРОСВЕ'ТСКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.*— борынгылык, иске заман, борын заман; *отпечаток старосветскости* — иске заман билгесе.

**СТАРОСЕ'ЛЬЕ** *ср.*— 1. күптән халык яшәп килә торган урын, күптән халык урнашкан урын; 2. иске авыл урыны.

**СТАРОСЛАВЯ'НСКИЙ** *лингв.*— 1. борынгы славян ...-ы; *старославянский язык* — борынгы славян теле; 2. борынгы славян

телендә язылган; *памятники старославянской письменности* — борынгы славян телендә язылган памятниклар.

**СТАРОСЛУ'ЖАЩИЙ** — күптән хезмәт итүче.

**СТА'РОСТА** *м.*— староста (берәр төрле зур булмаган коллективның эшләрен алып бару, житәкчелек итү өчен сайлап яки билгеләп куелган кеше); *сельский староста* — авыл старостасы (революциягә кадәр); *староста курса* — курс старостасы (уку йортында).

**СТАРОСТА'Т** *м.*— старостат (уку йортларында сайланган группа старосталарыннан торган оешма).

**СТАРОСТИ'ХА** *ж. простореч.*— староста хатыны.

**СТА'РОСТЬ** *ж. мн.* нет — картлык. ◇ **На старости лет** — картлык көнендә (көнендә, көнемдә). **Собачья старость** — к. собачий.

**СТАРТ** *м.*— старт (1. йөгерү, йөзү һ. б. ш. спорт ярышы башлану моменты; 2. очу аппаратының очып китү моменты; 3. спорт ярышы башлана торган урын, сызык).

**СТА'РТЕР** *м.*— стартер (1. спорт ярышы башлануын белдереп сигнал бирүче кеше; 2. *тех.* автомобиль һәм самолёт двигательләрен механик рәвештә эшләтә башлау өчен хезмәт итә торган җайланма).

**СТАРТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спорт., ав.*— старт алу, старт ясау.

**СТА'РТОВЫЙ** *спорт., ав.*— старттагы, старт линиясен күрсәтә торган; *стартовая лодка* — старттагы көймә, старт линиясен күрсәтә торган көймә.

**СТАРУ'ХА** *ж.*— карчык.

**СТАРУШЕ'НЦИЯ** *ж. простореч. фам.*— к. старуха.

**СТАРУ'ШЕЧИЙ** — карчык ...-ы, карчыклар ...-ы; *старушечий голос* — карчык тавышы.

**СТАРУ'ШКА** *ж.*— к. старуха.

**СТАРУШО'НКА** *ж. разг.*— к. старуха.

**СТА'РЧЕСКИЙ** — 1. картлык...-ы; *старческий маразм* — картлык маразмы; 2. карт кешегә хас; карт кеше ...-ы; *старческие глаза* — карт кеше күзләре; 3. карт кешесыман, картларча ...; *старческая улыбка* — картларча елмаю; 4. карт; *старческое лицо* — карт чырай.

**СТА'РЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — картлык.

**СТА'РШИЙ** — 1. олы; өлкән; *мой старший брат* — минем олы абыем; 2. иң борынгы; *старший список летописи* — елъязмаларның иң борынгы күчермәсе; 3. өлкән; *старший рабочий* — өлкән эшче; 4. югары, иң югары; *старший класс* — югары класс; 5. зур, иң зур; *старшая карта* — зур карта; 6. *в знач. сущ. мн.* зурлар, олылар, өлкәннәр; *брать пример со старших* — өлкәннәрдән үрнәк алу; 6. *в знач. сравн. ст. устар. (старше)* олырак.

**СТАРШИНА'** — 1. *м.* старшина (а. *дореввол.* берәр төрле профессиональ берләшмәнең, сословие оешмасының эшләре белән җитәкчелек итү өчен сайлап куелган кеше, башлык; *волостной старшина* — волость старшинасы; б. өлкән эшче; в. хәрби звание); 2. *ж. собир. истор.* старшиналар (гаскәрдә җитәкче урын тотучы таза тормышлы казаклар катлавы).

**СТАРШИ'НСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— старшиналык, старшина званиесе (яки вазифасы).

**СТАРШИНСТВО'** *ср. мн.* нет — (яшь, хезмәт яки звание ягыннан) олылык.

**СТАРШО'Й** — к. старший 1, 2, 3, 4.

**СТА'РЫЙ** — 1. карт; *старый человек* — карт кеше; 2. к. старческий 2; 3. иске; *старое платье* — иске күлмәк; *старая тема* — иске тема; *старые друзья* — иске дуслар; 4. күптән үткән, элеккеге; *старые годы* — элеккеге еллар; 5. иске, элеккеге; *старое настроение* — элеккеге настроение; *старый начальник* — элеккеге начальник. 6. күптәнге, иске; *он—старый спортсмен* — ул күптәнге спортсмен; 7. *в знач. сущ. мн.* картлар. ◇ **По старой памяти** — к. память. **По-старому** — искечә, элеккечә. **Стар и мал или старый и малый** — карты-яше. **Старый свет** — Иске дөнья (Европа, Азия һәм Африка).

**СТАРЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир. разг.*— 1. иске-моски, иске әйберләр; *торговец старьём* — иске-моски белән сату итүче; 2. *пренебр.* борынгы әйберләр, антиквар әйберләр; 3. *простореч. фам. пренебр.* карт-коры, картлар.

**СТАРЬЁВЩИК** *м.*, **СТАРЬЁВЩИЦА** *ж.*— 1. иске-моски белән сату итүче; *лавка старьёвщика* — иске-моски белән сату итүченең кибете; 2. *разг. ирон.* борынгы әйберләр һәвәскәре, антиквар әйберләр һәвәскәре.

**СТАСКА'ТЬ** *сов. разг.*— (бер урынга) ташу, ташып бетерү, ташып кую.

**СТАСКА'ТЬСЯ** *сов. простореч. вульг.*— барып кайту.

**СТА'СКИВАТЬ** *несов.*— 1. к. стаскать; 2. к. стащить 1, 2, 3, 4, 5.

**СТА'СКИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. (бер урынга) ташылу, ташып бетерелү; 2. сөйрәп төшерелү; 3. тартып чыгарылу; 4. тартып алыну.

**СТАСОВА'ТЬ** *сов.*— аралаштыру, бутау (уен карталарын).

**СТАСОВА'ТЬСЯ** *сов. карт. арго* — аралашу, буталу (уен карталары турында).

**СТАСО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. карт. арго* — к. стасоваться.

**СТАТА'РНЫЙ** *педаг.*— аңлатмалы, аңлатмалар биреп ...; *статарное чтение греческих авторов* — грек авторларын(ың әсәрләрен) аңлатмалар биреп уку.

**СТАТЕ'ЙКА** *ж. разг.*— 1. кечкенә мәкалә, зур булмаган мәкалә; 2. *фам. пренебр.* мәкалә, мәкалә кисәге.

**СТАТЕ'ЙНЫЙ** *книж. офиц.*— статьялар тәртибендә урнаштырылган, параграфлар тәртибендә урнаштырылган; статьялар...-ы; *статейный список* — статьялар исемлеге.

**СТАТИ'В** *м.*— к. штатив.

**СТА'ТИКА** *ж. мн.* нет — статика (1. *мех.* җисемнәрнең тигезлек саклау шартлары турында теоретик механиканың бер бүле-

ге; 2. тынычлык халәте, тыныч тору халәте).

**СТАТИ'СТ** *м.* — статист (1. *театр.* театр сәхнәсендә сүзсез кечкенә рольне башкаручы кеше; 2. *презрит.* кеше сүзе буенча гына эш итүче, бер дә әһәмияте булмаган кеше).

**СТАТИ'СТИК** *м.* — статистик, статистика белгече.

**СТАТИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — 1. статистика (а кешелек җәмгыятенең һәм халык хуҗалыгының сан ягыннан үзгәрешен өйрәнә торган фән; б. *устар.* дәүләтнең халкы, строе, экономикасы турындагы фән); 2. санын алу, сан ягыннан исәпкә алу; ***статистика употребления предлогов у русских писателей*** — рус язучыларының әсәрләрендә кулланылган бәйлекләрне сан ягыннан исәпкә алу.

**СТАТИСТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. статистик; ***статистическая таблица*** — статистик таблица; 2. статистика ...-ы; ***статистический отдел*** — статистика бүлеге.

**СТАТИ'СТКА** *ж.* — к. статист.

**СТАТИ'СТЫЙ** *спец.* — яхшы торыклы, сөлек кебек (ат турында).

**СТАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *мех.* статик; статика законнарына нигезләнеп ясалган; ***статический расчёт*** — статика законнарына нигезләнеп ясалган исәп; 2. *перен. книж.* статик (күренешләрнең эчке мөнәсәбәтен аларның үсешенә бәйсез рәвештә тикшерә торган); ***статическое изучение*** — статик өйрәнү. ◇ **Статическое чувство** *науч.* — статик тойгы (кешеләрдә һәм хайваннарда гәүдәнең тигезлеген саклау тойгысы).

**СТАТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — статиклык.

**СТАТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. статический 2.

**СТА'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — зифа буйлылык, матур сынлылык.

**СТА'ТНЫЙ** — зифа буйлы, килешле сынлы, матур сынлы.

**СТА'ТОР** *м. тех.* — статор (электр машинасының әйләнми торган өлеше).

**СТАТОСКО'П** *м. физ* — статоскоп (барометрның бер төре).

**СТА'ТОЧНЫЙ: статочное ли дело?** *старин. обл.* — мөмкинме соң? ярыймы соң? юл куярга ярыймы соң? килешкән эшме соң?

**СТАТС-ДА'МА** *ж. дореволь.* — статс-дама (патша сараенда патша хатыны свитасында булган югары катлау хатыннарына бирелә торган звание).

**СТА'ТСКИЙ** — 1. *устар.* к. штатский; 2. *дореволь.* статский; ***статский советник*** — статский советник.

**СТАТС-СЕКРЕТАРИА'Т** *м. дореволь.* — статс-секретариат, статс-секретарь канцеляриясе (идарәсе).

**СТАТС-СЕКРЕТА'РЬ** *м.* — статс-секретарь (1. *дореволь.* патшаның телдән әйтелгән боерыкларын игълан итәргә хокукы булган югары дәрәҗәле чиновник; 2. *дореволь.* Дәүләт Советы каршындагы Дәүләт канцеляриясе бүлеге белән идарә итүче чиновник; 3. кайбер капиталистик илләрдә һәм император заманындагы Германиядә — министр).

**СТАТУ'Й** *м. просторечь.* — к. истукан.

**СТА'ТУС-КВО'** *м. нескл. полит., право* — статус-кво (мәгълүм бер вакыт эчендә яшәп килгән яки яшәп килә торган хәл).

**СТАТУ'Т** *м.* — 1. *право, полит.* статут, төп закон; 2. *офиц.* статут, положение (берәр нәрсә турында).

**СТАТУ'ТНЫЙ** *право, полит.* — статут..., төп закон белән билгеләнә торган; ***статутное право*** — статут хокукы.

**СТАТУЭ'ТКА** *ж.* — статуэтка, кечкенә статуя, кечкенә сын (кырып, эвәләп яки коеп ясалган).

**СТА'ТУЯ** *ж.* — статуя, сын (кырып яки коеп ясалган).

**СТАТЬ** I *сов.* — 1. басу, килеп басу, тору; ***стань сюда*** — бире бас; ***стать у ворот*** — капка төбенә басу; 2. сыю, урнашу; ***диван в этой комнате не станет*** — диван бу бүлмәгә сыймас; 3. туктау; тукталу; ***часы стали*** — сәгать туктаган; ***дело стало*** — эш тукталды; 4. башлау; ***я стал слабеть и здоровьем*** (Л. Толстой) — минем сәламәтлегем дә начарлана башлады; 5. булу; ***что с ним стало за этот год?*** — ни булды аңа быел?; 6. *в знач. вспомогат. глагола* ***„быть"***; киләчәк заман ***стану, станешь, станет, станем, станете, станут*** сүзләре инфинитив формасында куелган төп фигыль алдында килсә, ул фигыльдән киләчәк заманның кушма формасын ясыйлар; ***стану сказывать я сказки, песенки спою*** (Лермонтов) — әкиятләр сөйләрмен, җырлар җырлармын; 7. *безл.* бетү, калмау, юк булу, юкка чыгу; ***не стало больше ни сил, ни терпения*** — артык көчем дә, түземлегем дә калмады; 8. *(с отриц.)* үлү, вафат булу; ***ещё в прошлом году его не стало*** — ул үткән елны ук үлде; 9. *просторечь.* ...-га төшү (хак турында); ***до Москвы доехать тебе станет рублей сорок*** (Гончаров) — Москвага барып җитү сиңа кырык сумнарга төшәр; 10. *обл.* җитү, булу; ***стала ночь*** — төн җитте. ◇ **Стать на колени** — тезләнү, тез чүгү. **Стать на якорь** — якорь салу, якорь салып туктау. **Стать в тупик** — аптырап калу. **Стать на дыбы** — үрә тору. **Стать на короткую ногу** — бик якын дуслашып китү. **Стать на ноги** — аякка басу, үз алдына яши башлау. **Это мне станет в копеечку** — бу миңа кыйммәткә төшәр. **Во что бы то ни стало** *перен.* — ни генә булмасын, ничек кенә булса да. **Стало быть** *ввод. сл. разг.* или **стало** *ввод. сл. просторечь.* — димәк, димәк ки, шулай итеп. **Станет с него** (с тебя, с меня) *разг. фам.* — аңардан (синнән, миннән) булыр ул, көт тә тор. **Не привыкать стать** *разг.* — күптән ияләнгән инде. **Вы что-то не веселы стали** (Грибоедов) — сез ни өчендер күңелсезләнеп киттегез. **Мне станет** — миңа җитеп торыр, миңа җитте.

**СТАТЬ** II *ж. только ед.* — сын-сыйфат, тән төзелеше, гәүдә. ◇ **Под стать** ***кому-чему*** — туры килә, туры килеп тора, бердәй. **Пойти на стать** *просторечь. фам.* —

рәтләнеп китү, җайга салыну, җайга салынып китү.

**СТАТЬ** III *ж. устар.* — (берәр нәрсәнең) характеры, сыйфаты. ◇ **С какой стати?** — нигә? ни өчен? ни сәбәптән?

**СТАТЬИ'ШКА** *ж. разг. пренебр.* — к. статейка.

**СТА'ТЬСЯ** *сов., чаще безл. разг.* — булу; *что сталось с ним?* — ни булды аңа? ◇ **Может статься** *ввод. сл. разг.* — бәлки.

**СТАТЬЯ'** *ж.* — 1. мәкалә; *передовая статья* — баш мәкалә; 2. статья (юридик документның, законның, сметаның, сүзлекнең һ. б. аерым бер бүлеге); 3. чыганак, тармак; *животноводство — выгодная статья дохода в сельском хозяйстве* — терлекчелек авыл хуҗалыгының күп доход бирә торган тармагы; 4. *перен. разг. фам.* эш, очрак; *морочить полоумного не хитрая статья* (Некрасов) — юләр кешенең башын әйләндерү кыен эш түгел ул; *надо поехать — статья подходящая!* (Некрасов) — уңайлы очрак — китәргә кирәк! 5. статья; *матрос первой статьи* — беренче статья матрос; 6. к. стать II. ◇ **Особь статья** — к. особь. **По всем статьям** *разг.* — һәрьяклап, һәр яктан да.

**СТАФИЛОКО'КК** *м. бакт.* — стафилококк (бактериянең бер төре).

**СТАЦИОНА'Р** *м.* — стационар (һәрвакыт бер урында эшли торган учреждение).

**СТАЦИОНА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — үзгәрешсезлек, үзгәрешсез булу.

**СТАЦИОНА'РНЫЙ** — 1. *науч.* үзгәрешсез, үзгәрми торган; *стационарное состояние* — үзгәрми торган хәл; 2. стационар..., бер урында эшли торган; *стационарная библиотека* — стационар китапханә; 3. *мед.* больницада ятып дәваланучы; *стационарный больной* — больницада ятып дәваланучы авыру; 4. *мед.* стационар ...; больницада ятып дәваланучылар ...-ы; *стационарное отделение* — стационар бүлек; 5. *мед.* стационарда эшләүче; *стационарный врач* — стационарда эшләүче врач.

**СТАЦИОНЕ'Р** *м. мор.* — стационер, сакчы судно, сакта торучы судно (колония портларында сакчы яки полиция хезмәтен үти торган судно).

**СТАЧА'ТЬ** *сов. сапож., порт.* — каеп чыгу, тегеп чыгу.

**СТА'ЧЕЧНИК** *м.*, **СТА'ЧЕЧНИЦА** *ж.* — стачкачы, стачкага катнашучы.

**СТА'ЧЕЧНЫЙ** — 1. стачка ...-ы; *стачечный комитет* — стачка комитеты; 2. стачкачы ...-ы, стачкачылар ...-ы, стачкага катнашучылар ...-ы; *стачечная касса* — стачкачылар кассасы.

**СТА'ЧИВАТЬ** *несов.* — к. сточить.

**СТА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *спец.* к. сточиться; 2. *страд.* кайрап тигезләнү, чарлап тигезләнү, игәүләп тигезләнү.

**СТА'ЧКА** I *ж.* — 1. *простореч. неодобр. (действие)* к. стакнуться; 2. стачка, забастовка, эш ташлау.

**СТА'ЧКА** II *ж. сапож., порт.* — 1. *только ед. (действие)* к. стачать; 2. җөй, тегелгән урын, каелган урын.

**СТАЩИ'ТЬ** *сов.* — 1. сөйрәп илтү, өстерәп илтү, сөйрәп төшерү; *стащить мешок картошки в подвал* — бер капчык бәрәңгене идән астына сөйрәп төшерү; 2. тартып чыгару; *стащить пароход с мели* — пароходны сайлыкка утырган җиреннән тартып чыгару; 3. *разг.* илтеп кую; *стащил свои вещи на вокзал* — әйберләремне вокзалга илтеп куйдым; 4. *разг. фам. (сводить куда-н.)* өстерәп илтү, алып бару; 5. тартып алу, тартып төшерү; *стащить одеяло с сонного* — йоклап яткан кешенең өстеннән юрганын тартып алу; 6. чәлдерү (урлау мәгънәсендә); *кто стащил мой карандаш?* — кем минем карандашымны чәлдерде?

**СТАЩИ'ТЬСЯ** *сов. простореч. фам.* — 1. (сөйрәлеп) төшү; *старик насилу с крыльца стащился* — карт көч-хәл белән генә болдырдан төште; 2. салыну, тартып алыну; *сапог узок, наденешь, потом с ног не стащится* — итек тар, кисәң, соңыннан аягыңнан салынмас.

**СТА'Я** *ж.* — көтү, өер, төркем.

**СТА'ЯТЬ** *сов.* — эрү, эреп бетү (кар һәм боз турында).

**СТВОЛ** *м.* — 1. кәүсә; *ствол берёзы* — каен кәүсәсе; 2. *воен.* көпшә; *ружейный ствол* — мылтык көпшәсе; 3. *спец.* к. брандспойт; 4. *архит.* багана (колоннаның капителе белән нигезе арасындагы өлеше); 5. *горн.* ствол, шахта үзәге (шахтаның җир өстеннән алып төбенә хәтле булган өлеше); 6. *тех., горн.* (берәр нәрсәнең) агынтысы; *ствол свежего воздуха* — саф һаваның агынтысы; 7. *анат.* канал, багана; *нервный ствол* — нерв баганасы, нерв каналы.

**СТВОЛИ'СТЫЙ** — күп кәүсәле.

**СТВОЛОВА'ТЫЙ** *спец.* — кәүсәсыман, каты.

**СТВОЛОВО'Й** *спец.* — 1. к. стволовый; 2. *в. знач. сущ.* стволда эшләүче эшче; шахта стволында эшләүче; 3. *в знач. сущ.* к. ствольщик.

**СТВОЛО'ВЫЙ** — 1. кәүсәле; 2. *горн* стволлы.

**СТВО'ЛЬНЫЙ** — 1. кәүсә ...-ы; *ствольная часть дерева* — агачның кәүсә өлеше; 2. көпшә ...-ы; *ствольная коробка ружья* — мылтыкның көпшә коробкасы; 3. багана ...-ы; *ствольная часть колонны* — колоннаның багана өлеше.

**СТВО'ЛЬЩИК** *м. спец.* — брандспойтчы, брандспойтта эшләүче (янгын сүндерүче).

**СТВОР** *м.* — 1. *чаще мн.* к. створка; 2. *только ед. (действие)* к. створить 2; 3. *спец.* елганың су режимын тикшерә торган урын.

**СТВОРА'ЖИВАТЬ** *несов. спец.* — к. творожить.

**СТВОРА'ЖИВАТЬСЯ** *несов. спец.* — к. творожиться.

**СТВОРИ'ТЬ** *сов.* — 1. *обл.* ябу (тәрәзә капкачларын, ике якка ачылмалы ишекне һ. б.); 2. берсе артыннан икенчесе күренмәслек итеп кую (мәсәлән, маякларны).

**СТВОРИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *обл.* ябылу (тә-

рәзә капкачлары, ике якка ачылмалы ишек турында); 2. берсен-берсе каплап тору, берсе артыннан икенчесе күренмәү (мәсәлән, маяклар турында).

**СТВО'РКА** *ж.* — 1. капкач (ике якка ачылмалы ишекнең, капканың һ. б.) бер ягы; 2. *устар.* китап(ның) каптырмасы.

**СТВОРО'ЖИТЬ** *сов. спец.* — к. творожить.

**СТВОРО'ЖИТЬСЯ** *сов. спец.* — к. творожиться 1.

**СТВО'РЧАТЫЙ** — ике якка ачылмалы; *створчатые двери* — ике якка ачылмалы ишек.

**СТВОРЯ'ТЬ** *несов.* — к. створить.

**СТВОРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. створиться.

**СТЕАРИ'Н** *м. мн.* нет — стеарин (шәм ясауга китә торган май).

**СТЕАРИ'НОВЫЙ** — 1. стеарин ...-ы; *стеариновая кислота* — стеарин кислотасы; *стеариновый завод* — стеарин заводы; 2. стеарин ..., стеариннан ясалган; *стеариновая свеча* — стеариннан ясалган шәм.

**СТЕБАНУ'ТЬ** *сов. однокр. обл.* — (чыбыркы, чыбык һ. б. ш. белән) сыдыру, сыдырып җибәрү, сыдырып алу.

**СТЕБА'ТЬ** *несов. обл.* — (чыбыркы, чыбык һ. б. ш. белән) кисү, яру (кыйнау мәгънәсендә).

**СТЕ'БЕЛЬ** *м. бот.* — сабак (үсемлектә). ◇ **Подземный стебель** *бот.* — тамыр. **Главный стебель** *бот.* — кәүсә.

**СТЕБЕЛЬКО'ВЫЙ, СТЕ'БЕЛЬНЫЙ, СТЕБЕ'ЛЬЧАТЫЙ** *бот.* — сабаклы.

**СТЕБЛЕВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х. бот.* — сабаклану, сабак чыгару, сабакка утыру.

**СТЕБЛЁВЫЙ** *бот.* — 1. к. стебельчатый; 2. сабактагы, сабакта урнашкан.

**СТЕБЛИ'СТЫЙ** — күп сабаклы.

**СТЕБЛО'** *ср. обл.* — 1. сап, тотка; *стебло ложки* — кашык сабы; 2. *ед. в знач. собир.* камыл; 3. үзәк; *стебло птичьего пера* — каурый үзәге.

**СТЕГА'** *ж. обл.* — сукмак.

**СТЕГА'ЛЬНЫЙ** *спец.* — сыру ...-ы, сырганда кулланыла торган; *стегальные пяльцы* — сырганда кулланыла торган киергә.

**СТЕГА'ЛЬЩИК** *м.*, **СТЕГА'ЛЬЩИЦА** *ж.* — (юрган, кием) сыручы, (юрган, кием) сыру эше остасы.

**СТЁГАНКА** *ж. обл.* — сырма.

**СТЕГАНОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — стеганографик, шартлы (яшерен) билгеләр белән язылган; *стеганографическое письмо* — шартлы билгеләр белән язылган хат.

**СТЕГАНОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — стеганография, шартлы (яшерен) билгеләр белән язу.

**СТЕГАНУ'ТЬ** *сов. однокр. разг.* — к. стебануть.

**СТЁГАНЫЙ** — сырган; *стёганое одеяло* — сырган юрган.

**СТЕГА'ТЬ** I *несов.* — (чыбыркы, чыбык һ. б. ш. белән) кисү, яру, кыйнау.

**СТЕГА'ТЬ** II *несов.* — сыру; *стегать одеяло* — юрган сыру.

**СТЕГА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — сырылу (юрган турында).

**СТЕГНУ'ТЬ** *сов. однокр. разг.* — к. стебануть.

**СТЁЖКА** I *ж. порт.* — 1. *только ед.* к стегать II; 2. җөй; *крупная стёжка* — эре җөй.

**СТЁЖКА** II *ж. обл.* — сукмак.

**СТЕЖО'К** *м. порт.* — бер чәнчем, бер атлам (тегү эшендә).

**СТЕЗЯ'** *ж. книж. ритор.* — юл.

**СТЕ'КА** *ж. искус.* — стека (скульптура эшендә кулланыла торган агач таякчык).

**СТЕКА'ТЬ** *несов.* — к. стечь.

**СТЕКА'ТЬСЯ** *несов.* — к. стечься.

**СТЕКЛИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — күн шомартучы (эшче).

**СТЕКЛИ'ТЬ** *несов.* — 1. *спец.* күн шомарту; 2. *(застеклять)* пыяла кую, пыяла куйдыру.

**СТЕКЛИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. шомартылу (күн турында); 2. пыяла куелу.

**СТЕКЛО'** *ср.* — 1. пыяла; 2. *только ед. собир.* **спец.** пыяла әйберләр, пыяладан ясалган әйберләр, пыяла савыт-саба.

**СТЕКЛОВА'ЛЬНЫЙ** *спец.* — к. стеклоеварный.

**СТЕКЛОВА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — к. стекловарщик.

**СТЕКЛОВА'Р** *м. спец.* — пыяла кайнатучы (пыяла промышленносте эшчесе).

**СТЕКЛОВАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — пыяла кайнату.

**СТЕКЛОВА'РНЫЙ** *спец.* — 1. пыяла ...-ы; *стекловарное производство* — пыяла производствосы; 2. пыяла кайната торган, пыяла кайнату ...-ы; *стекловарная печь* — пыяла кайната торган мич.

**СТЕКЛОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — пыяласымак булу.

**СТЕКЛОВА'ТЫЙ** *горн. спец.* — пыяласыман, пыялага охшаган.

**СТЕКЛОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — эретеп пыялага әйләндерү (әвереллдерү); *стекловать песок* — комны эретеп пыялага әвереллдерү.

**СТЕКЛОВА'ТЬСЯ** *спец.* — 1. *сов.* и *несов.* эреп пыялага әверелү; 2. *несов. страд.* эретеп пыялага әйләндерелү (әвереллдерелү), эретеп пыяла ясалу.

**СТЕКЛОВИ'ДНЫЙ** — к. стеклоеватый.

**СТЕКЛОВЫДУВА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — к. стеклодув.

**СТЕКЛО'ГРАФ** *м.* — стеклограф, пыяла басма.

**СТЕКЛОГРАФИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — стеклографта басу, стеклографта бастыру.

**СТЕКЛОГРАФИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — стеклографта басылу, стеклографта бастырылу.

**СТЕКЛОГРАФИ'СТ** *м.*, **СТЕКЛОГРАФИ'СТКА** *ж.* — стеклографта эшләүче.

**СТЕКЛОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — стеклографик.

**СТЕКЛОГРА'ФИЯ** *ж. спец.* — стеклография (1. *только ед.* стеклографта басу; 2. стеклографта басу предприятиесе; 3. стеклографта басылган язма, оттиск).

**СТЕКЛОДЕ'Л** *м. спец.* — пыяла ясаучы (пыяла промышленносте эшчесе).

**СТЕКЛОДЕ'ЛАТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — пыяла ...-ы; пыяла ясау ...-ы; *стеклоделательный завод* — пыяла заводы.

**СТЕКЛОДЕ'ЛИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — пыяла ясау, пыяла эшләп чыгару.

**СТЕКЛОДЕ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — пыяла ...-ы, пыяла эшләп чыгару ...-ы; *стеклодельная промышленность* — пыяла промышленносте.

**СТЕКЛОДУ'В** *м. спец.* — пыяла өрүче (өреп пыяладан төрле әйберләр ясаучы).

**СТЕКЛОДУ'ВНЫЙ** *спец.* — пыяла әйберләр ...-ы (өреп пыяладан төрле әйберләр ясый торган); *стеклодувный завод* — пыяла әйберләр заводы.

**СТЕКЛОЗАВО'Д** *м. спец.* — пыяла заводы.

**СТЕКЛОМА'ССА** *ж. мн.* нет, *спец.* — пыяла массасы.

**СТЕКЛОПЛА'В** *м. спец.* — к. стекловар.

**СТЕКЛОПЛАВИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — к. стекловарный.

**СТЕКЛОРЕ'ЖУЩИЙ** *спец.* — пыяла кисә торган; *стеклорежущий инструмент* — пыяла кисә торган инструмент.

**СТЕКЛОРЕ'З** *м. спец.* — 1. пыяла кисүче (эшче); 2. пыяла кискеч, пыяла кисә торган инструмент.

**СТЕКЛОФАРФО'РЩИК** *м. спец.* — пыяла-фарфор әйберләр ясаучы (пыяла-фарфор промышленносте эшчесе).

**СТЕКЛУ'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — эреп пыялага әверелү, эреп пыялага әверелә алу.

**СТЕКЛУ'ЕМЫЙ** — эреп пыялага әверелә торган, эреп пыялага әверелә ала торган.

**СТЁКЛЫШКО** *ср. разг.* — 1. к. стекло; 2. *(кусочек стекла)* пыяла кисәге. ◇ **Как стёклышко** *простореч. фам. шутл.* — 1. көзге кебек (чип-чиста, бик саф); 2. *перен.* ап-аек.

**СТЕКЛЯНЕ'ТЬ** *несов.* — пыялалану, тону (күзләр турында).

**СТЕКЛЯ'ННИЦА** *ж. зоол.* — пыялач (күбәләк).

**СТЕКЛЯ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — җансызлык, рухсызлык; *стеклянность взгляда* — күз карашының җансызлыгы.

**СТЕКЛЯ'ННЫЙ** — 1. пыяла...-ы; *стеклянная масса* — пыяла массасы; 2. пыяла ..., пыяладан ясалган; *стеклянный стакан* — пыяла стакан; 3. пыяла ..., җансыз; *стеклянные глаза* — пыяла күзләр; 4. к. стекольный. ◇ **Стеклянный блеск** — пыяла кебек ялтырау, пыяла ялтыравыгы. **Стеклянная бумага** *спец.* — пыялалы кәгазь (шомарту өчен кулланыла).

**СТЕКЛЯ'РУС** *м. собир. мн.* нет — пыяла мәрҗән.

**СТЕКЛЯ'РУСНИК** *м.*, **СТЕКЛЯ'РУСНИЦА** *ж. спец.* — пыяла мәрҗән остасы, пыяла мәрҗән ясаучы.

**СТЕКЛЯ'РУСНЫЙ** — 1. пыяла мәрҗән ...-ы; *стеклярусное производство* — пыяла мәрҗән производствосы; 2. пыяла мәрҗәннән ясалган; *стеклярусные украшения* — пыяла мәрҗәннән ясалган бизәкләр.

**СТЕКЛЯ'ШКА** *ж. разг. фам.* — пыяла кисәге; кечкенә пыяла әйбер.

**СТЕКО'ЛЬНЫЙ** — 1. пыяла ...-ы; *стекольный завод* — пыяла заводы; 2. пыяла ..., пыяладан ясалган; *стекольные товары* — пыяладан ясалган товарлар.

**СТЕКО'ЛЬЩИК** *м.* — 1. пыялачы, пыяла куючы; 2. пыяла ясаучы (пыяла промышленносте эшчесе); 3. *спец.* пыялалы кәгазь ясаучы.

**СТЕ'ЛЕЧНЫЙ** *спец.* — олтырак ...-ы, олтыраклык, олтыракка китә торган; *стелечная кожа* — олтыракка китә торган күн.

**СТЕЛИ'ТЬ** *несов. простореч.* — к. стлать.

**СТЕЛИ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. стлаться.

**СТЕЛЛА'Ж** *м.* — стеллаж (1. *спец.* бер-бер өсле урнаштырылган киштәләр; *в библиотеках книги хранятся на стеллажах* — көтепханәләрдә китаплар стеллажларда саклананалар; 2. *спец.* берәр нәрсәне бастырып куелган килеш саклау өчен хезмәт итә торган җайланма; 3. *архит. плот.* биналарда яки йорт салганда: ике терәккә салынган балка).

**СТЕЛЛИ'Т** *м. мн.* нет, *тех.* — стеллит (кискеч кораллар ясауга китә торган гадәттән тыш каты металл эретмә).

**СТЕ'ЛЬКА** *ж.* — олтырак (аяк киеменең эченә куелган күн, постау яки чүпрәк). ◇ **Как стелька** *разг. фам.* — дөм исерек, лаякыл исерек.

**СТЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — буазлык (сыерларга карата).

**СТЕ'ЛЬНАЯ** *с.-х.* — буаз (сыер).

**СТЕЛЮ'ГА** *ж. спец.* — 1. к. слега; 2. түшәмә, басма (йорт, каралты салганда эшчеләр басып эшли торган такталар).

**СТЕМ** *м. мор.* — к. форштевень.

**СТЕМНЕ'ТЬ** *сов.* — 1. караңгы төшү, караңгылану, караңгыланып җитү; *скоро стемнеет* — тиздән караңгы төшәр; 2. *простореч. обл. (потемнеть)* каралу.

**СТЕНА'** *ж.* — 1. стена; *наружная стена* — тышкы стена; 2. *обл.* 6—12 аршын озынлыктагы кнндер кисәге. ◇ **В стенах** *чего книж.* — ...-да, ... эчендә; *в стенах университета* — университетта. **В четырёх стенах** (сидеть, жить) *перен.* — дүрт стена эчендә утыру, дүрт стена эчендә яшәү (беркем белән дә аралашмау). **Зарубить на стене** — колакка киертеп кую, колакка алка итеп тагу. **Как на каменную стену** (надеяться, положиться) *разг.* — бик нык ышану. **Как об стену** (или **в стену** или **стене** или **от стены**) **горох** *перен. разг.* — стенага борчак сипкәндәй; колагына да элми. **На стену лезть** *перен. разг.* — күтәрелеп бәрелү. **Прижать или припереть к стене** — к. припереть. **Стена в стену** *разг.* — стена артында гына, янәшә. **Между ними выросла стена** *перен. книж.* — аларның арасы бозылды, алар арасында каршылыклар туды.

**СТЕНА'ТЬ** *несов. книж.* — ыңгырашу.

**СТЕНГАЗЕ'ТА** *ж.* — стенгазета, стена газетасы.

**СТЕНГАЗЕ'ТНЫЙ** — стена газетасы...-ы, стена газетасында язылган; *стенгазетная заметка* — стена газетасында язылган мәкалә.

**СТЕНГАЗЕ'ТЧИК** *м. разг.*—стена газетасында эшләүче.

**СТЕНД** *м.* — стенд (1. *тех.* заводта җыелган машиналарны сынау урыны; 2. күргәзмәдә экспонатлар, диаграммалар, картограммалар куелган урын, щит, такта һ. б.).

**СТЕНДИ'СТ** *м. спец.*—стендист, стендчы (күргәзмәгә килүчеләргә стендлардагы материаллар турында аңлатмалар бирүче).

**СТЕ'НКА** *ж.* — 1. к. стена 1; 2. *спорт.* стенка (гимнастик күнекмәләр ясау өчен стенага беркетелгән баскычсыман җайланма). ◇ **К стенке поставить** *кого разг.* — ату, атып үтерү.

**СТЕННИ'К** *м. обл.*—бүрәнә корты.

**СТЕННО'ВКА** *ж. разг.* — к. стенгазета.

**СТЕННО'Й** — 1. стена ...-ы; *стенная газета* — стена газетасы; 2. стенага ясалган, стенадагы; *стенная живопись* — стенадагы рәсемнәр (бизәкләр).

**СТЕНОБИ'ТНЫЙ** *истор.* — стена вата торган, стена ватып тишә торган; *стенобитные орудия* — стена вата торган кораллар.

**СТЕНОГРА'ММА** *ж.* — стенограмма (стенография юлы белән язылган язу, аерым билгеләр, кыскартмалар белән язылган язу).

**СТЕНОГРА'ММНЫЙ** — стенограмма ...-ы; *стенограммный материал* — стенограмма материалы.

**СТЕНО'ГРАФ** *м.* — стенограф (стенография юлы белән язучы).

**СТЕНОГРАФИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — стенография юлы белән язу, стенография юлы белән язып алу.

**СТЕНОГРАФИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — стенография юлы белән язылу, стенография юлы белән язып алыну.

**СТЕНОГРАФИ'СТ** *м. редко* — к. стенограф.

**СТЕНОГРАФИ'СТКА** *ж.*—стенографистка (стенография юлы белән язучы хатын-кыз).

**СТЕНОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — 1. стенография ...-ы; *стенографический алфавит* — стенография алфавиты; 2. стенографик, стенография юлы белән язып алынган; *стенографические отчёты* — стенография юлы белән язып алынган отчётлар; 3. *перен. разг. (совершенно точный, буквальный)* стенографик, сүзгә сүз (бирелгән).

**СТЕНОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — стенография (сөйләгәнне аерым билгеләр, кыскартмалар белән язу).

**СТЕНО'З** *м. мед.* — стеноз (организмда төрле каналларның тараюы).

**СТЕНО'ЗНЫЙ** *мед.*—стеноз ...-ы; *стенозные явления* — стеноз күренешләре.

**СТЕНОКАРДИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — стенокардия, күкрәк бакасы (йөрәк авыруы).

**СТЕНОПИ'СЕЦ** *м. живоп.* — стенага рәсемнәр ясаучы.

**СТЕНОПИ'СНЫЙ** *живоп.*—стенага рәсемнәр ясау ...-ы; *стенописное искусство* — стенага рәсемнәр ясау сәнгате.

**СТЕ'НОПИСЬ** *ж. мн.* нет, *живоп.*—стенага ясалган рәсемнәр.

**СТЕНОТИПИ'СТ** *м.*, **СТЕНОТИПИ'СТКА** *ж. спец.*—стенотипияче (сөйләгәнне стенография машинкасында басучы).

**СТЕНОТИПИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — стенотипик, стенография машинкасында басылган; *стенотипическое письмо* — стенотипик язу.

**СТЕНОТИ'ПИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.* — стенотипия (стенография машинкасында басылган язу).

**СТЕНЬ** *ж. обл.* — к. тень.

**СТЕ'НЬГА** *ж. мор.* — стеньга (мачтаның очына ялгана торган вертикаль борыс).

**СТЕПЕ'ННИЧАТЬ** *несов. просторечн. неодобр.* — олысымаклану; эре кылану.

**СТЕПЕ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет—салмак табигатьлелек, сабыр табигатьлелек, төплелек.

**СТЕПЕ'ННЫЙ**—1. салмак табигатьле, сабыр табигатьле, төпле; *степенная женщина*—сабыр табигатьле хатын кеше; 2. *разг.* тәртипле; *степенная жизнь* — тәртипле тормыш; 3. салмак, салмак кына...; *степенный поклон*—салмак кына баш ию; 4. урта; *степенный возраст* — урта яшь; 5. *истор.* дәрәҗәле; *степенный гражданин*—дәрәҗәле гражданин; 6. *старин.* урындагы (отставкага чыкмаган); *степенная голова* — урындагы шәһәр башлыгы.

**СТЕПЕ'НСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.* — 1. к. степенность; 2. *просторечн. доревол.* хөрмәтле ... әфәнде (сәүдәгәрләргә мөрәҗәгать итү сүзе).

**СТЕ'ПЕНЬ** *ж.* — дәрәҗә. ◇ **В значительной степени** — күбесенчә; башлыча. **В равной степени**—бертигез, бертигез дәрәҗәдә. **До какой степени**—шулкадәр. **До последней степени**—ахыр чиккәчә, соңгы чиккәчә. **Ни в какой степени или ни в малейшей степени** — һич, бөтенләй ... түгел.

**СТЕПНО'Й**—1. дала ...-ы; *степная растительность*—дала үсемлекләре; 2. даладагы; *степное село* — даладагы авыл.

**СТЕПНЯ'К** *м.*—1. *(человек)* дала кешесе, далада яшәүче кеше; 2. *(лошадь)* дала аты; 3. *обл. (степной кулик)* кыр кулигы, тәләтәвеч.

**СТЕПНЯ'ЧКА** *ж.*—1. к. степняк 1; 2. *с.-х.* дала бодае (көзге бодайның бер төре).

**СТЕПС** *м. мор.* — степс (судно палубасында мачта кую өчен оя, тишек).

**СТЕПЬ** *ж.* — дала.

**СТЕР** *м.* — стер, бер кубометр.

**СТРАХОВА'ТЬ** *несов.* — 1. страховкалау, страховать итү (бирәр нәрсәне яки кешене страховать итү турында договор төзү); *страховать имущество от пожара* — милекне янгыннан страховать итү; 2. *перен. разг. (предохранять)* (алдан) чарасын күреп кую, саклап калу; 3. *спорт.* саклап тору, страховкалау (гимнастикада — егылып имгәнүдән саклау).

**СТРАХОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — страховкалану, страховать ителү.

**СТРАХОВИ'К** *м.* — страховик (страховой оешмалар эшчесе; социаль страхование учреждениесе хезмәткәре).

**СТРАХОВИ'ТЫЙ** *обл.* — ямьсез, шыксыз, коточкыч кыяфәтле.

**СТРАХО'ВКА** *ж. разг.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. страховать; 2. *разг.* страховка, страховка договоры; *заключить страховку* — страховка договоры төзү; 3. страховка, страховка акчасы; *платить страховку* — страховка акчасы түләү; *получать страховку* — страховка акчасы алу; 4. *только ед. перен.* алдан чарасын күрү; алдан күрелгән чара, гарантия.

**СТРАХОВО'Й** — 1. страховка ...-ы, страхование ...-ы; *страховая премия* — страховка акчасы; *страховой агент* — страховка агенты; 2. страховой учреждение ...-ы; *страховой служащий* — страховой учреждение хезмәткәре; 3. *перен.* запас ...., страховой; *страховой семенной фонд* — запас орлык фонды.

**СТРАХО'ВЩИК** *м.* — страховщик (1. *эк. фин.* страховка акчасын түләүне үз өстенә алучы учреждение яки кеше; 2. *спорт.* гимнастика күнекмәләре башкаручыны егылып имгәнүдән саклап торучы кеше).

**СТРАШЕ'ННЫЙ** *обл., просторeч.* — бик куркыныч, коточкыч.

**СТРАШИ'ЛА** *м.* и *ж.* — к. страшилище.

**СТРАШИ'ЛИЩЕ** *м.* и *ср.* — коточкыч нәрсә, бик куркыныч нәрсә.

**СТРАШИ'ЛО** *м.* и *ср. просторeч.* — к. страшила.

**СТРАШИ'ТЬ** *несов.* — куркыту.

**СТРАШИ'ТЬСЯ** *несов.* — курку, кот очып тору.

**СТРАШЛИ'ВЫЙ** *обл.* — куркак, өркәк, өркүчән.

**СТРАШНЕ'НЕК** *разг. фам.* — коточкыч, куркыныч; бераз куркыныч.

**СТРА'ШНЫЙ** — 1. куркыныч, коточкыч; 2. *в знач. сказ. безл.* курка(м. сын), коты (*м. к*) оча; куркыныч; *страшно выйти мне из дому* — мин өйдән чыгарга куркам.

**СТРАЩА'ТЬ** *несов. просторeч.* — куркыту, котын алу.

**СТРЕ'ЖЕНЬ** *м. обл.* — елганың тирән урыны, елганың уртасы, фарватер.

**СТРЕЖНЕВО'Й** *обл.* — елганың тирән урынындагы, фарватердагы.

**СТРЕКА'ВА** *ж. обл.* — кычыткан.

**СТРЕКА'ВИТЬ** *несов. просторeч.* — кычыткан чагу.

**СТРЕКА'ВИТЬСЯ** *несов. просторeч.* — 1. к. стрекавить; 2. *страд.* кычытканнан чактырылу.

**СТРЕКА'ЛО** *ср. книж. устар.* — ук, чаккыч.

**СТРЕКА'ТЕЛЬНЫЙ** *зоол. анат.* — уклы; чага торган.

**СТРЕКА'ТЬ** *несов. просторeч.* — 1. к. стрекавить; 2. *обл.* сызу, шылу, таю (качып китү мәгънәсендә).

**СТРЕКА'Ч** *м.*: **задать** (или **дать**) **стрекача** *разг. фам.* — табан ялтырату, сызу, шылу, таю (качып китү мәгънәсендә).

**СТРЕКНУ'ТЬ** *однокр. просторeч.* — к. стрекавить..

**СТРЕКОЗА'** *ж.* — 1. чикерткә; 2. *перен. разг.* кыбырсык, тиктормас, чикерткә (бала турында).

**СТРЕКО'ЗИЙ, СТРЕКОЗИ'НЫЙ** — чикерткә ...-ы; *стрекозьи крылья* — чикерткә канатлары.

**СТРЕКОЗИ'ТЬ** *несов. разг. фам.* — тик тормау, кыбырсыклану.

**СТРЕ'КОТ** *м. мн.* нет — 1. чырылдау, безелдәү, чырылдаган тавыш, безелдәгән тавыш; 2. такылдау, такылдаган тавыш (атыш турында); 3. *перен. разг. фам.* такылдау, чәрелдәү.

**СТРЕКОТА'ТЬ** *несов.* — 1. чырылдау, безелдәү; 2. *перен. разг. фам.* такылдау, чәрелдәү.

**СТРЕКОТНЯ'** *ж. мн.* нет. *разг.* — к. стрекот.

**СТРЕКОТУ'ХА** *м.* и *ж. просторeч. фам. неодобр.* — чәрелдек, такылдык (өзлексез сөйләп торучы).

**СТРЕКУЛИ'СТ** *м. просторeч.* — 1. стрекулист, вак чиновник; 2. *пренебр.* үзенә кирәкне рәтле белүче, тыкшынучан кеше, әрсез кеше.

**СТРЕЛА'** *ж.* — 1. ук; *ранить стрелой* — ук белән яралау (җәядән атып яралау); *прямой, как стрела* — уктай туры, ук кебек туры; 2. *бот. спец.* кәүсә; сабак; 3. көпшә; *лук пошёл в стрелы* — суган көпшәләнә башлаган; 4. стрела (а. *тех.* йөк күтәрү кранының бер өлеше; б. *мор.* суга төшерү алдыннан терәкләрен алып бетергәч тә судноны стапельләрдә тота торган борыс; в. *спец.* төрле озын тар предметлар, шулай ук механизмнарның, корылмаларның рычаг, терәк, ыргыткыч булып хезмәт итә торган өлеше; г. бер төр экспресс поездның атамасы). ◇ **Парфянская стрела** *перен.* — парфян угы; туры сугу, оста әйтелгән сүз. **Стрела подъёма свода** или **стрела свода** *архит.* — гөмбәзнең биеклеге (гөмбәзнең иң югары ноктасы белән аның нигезе арасы).

**СТРЕЛЕ'Ц** *м.* — 1. стрелец, укчы (*истор.* XVI—XVII йөзләрдә Москва дәүләтендә — аерым хокуклар белән файдаланган гаскәри); 2. *астр.* Кавәс, Укчы (йолдызлык).

**СТРЕЛЕ'ЦКИЙ** *истор.* — стрелец ...-ы, стрелецлар ...-ы; *стрелецкий бунт* — стрелецлар бунты.

**СТРЕЛИ'ТЬ** *сов. обл.* — 1. к. выстрелить; 2. ату, атып үтерү.

**СТРЕ'ЛКА** *ж.* — 1. тел (сәгатьтә); *часовая стрелка* — сәгать теле; 2. тел; ук; *стрелка компаса* — компас угы; 3. ук (а.→формасындагы юнәлеш күрсәтү билгесе; б. тар һәм бик озын ярымутрау; в. *ж.-д.* тимер юлда рельс күчергеч; г. җәясыман пычкының боргычы); 4. к. стрела 1, 2; 5. *ветер. зоол.* йөрәк ите (ат тоягының аскы яктан икегә аерылуы).

**СТРЕЛКО'ВЫЙ** — 1. ату ... -ы; *стрелковый спорт* — ату спорты; 2. *воен.* укчы ...-ы, укчылар ...-ы; *стрелковый батальон* — укчылар батальоны.

**СТРЕЛОВИ'ДНЫЙ** — уксыман, укка охшаган, очлы.

**СТРЕЛОВО'Й** *спец.* — стреловой (йөк күтәрү механизмнарының стреласы белән идарә итүче).

**СТРЕЛО'К** *м.* — укчы, атучы.

**СТРЕЛОЛИ'СТ** *м. бот.* — ук яфрак, су угы.

**СТРЕЛООБРА'ЗНЫЙ** *книж.* — к. стреловидный.

**СТРЕЛОПОДО'БНЫЙ** *книж.* — к. стреловидный.

**СТРЕ'ЛОЧНИК** *м.*, **СТРЕ'ЛОЧНИЦА** *ж.* — 1. стрелочник (тимер юл стрелкасын күчереп торучы); 2. *перен.* гаепсездән гаепле кеше. ◇ **Стрелочник виноват** *ирон.* — стрелочник гаепле (берәр кимчелектә гаепле итеп түбән урындагы кешене күрсәтү).

**СТРЕ'ЛОЧНЫЙ** *ж.-д.* — рельс күчерү ...-ы, стрелка күчерү ...-ы; *стрелочные и сигнальные устройства на рельсах* — рельсларда стрелка күчерү һәм сигнал бирү җайланмалары.

**СТРЕЛЬБА'** *ж.* — 1. ату, атыш; *ружейная стрельба* — мылтыктан ату; *открыть стрельбу* — ата башлау; 2. *только ед. разг.* чатнау; *стрельба в ушах* — колаклар чатнау.

**СТРЕ'ЛЬБИЩЕ** *ср.* — ату урыны, атарга өйрәнү урыны.

**СТРЕЛЬНУ'ТЬ** *однокр. разг.* — 1. ату, бер тапкыр ату; атып җибәрү; *стрельнуть из ружья* — мылтыктан атып җибәрү; 2. чатнап китү; *стрельнуло в у'хе* — колагым чатнап китте.

**СТРЕ'ЛЬЧАТЫЙ** — 1. *архит.* очлаеп тора торган, а́ркасыман; *стрельчатые окна* — очлаеп тора торган (а́ркасыман) тәрәзәләр; 2. көпшәгә утырган, көпшәле; *стрельчатый лук* — көпшәгә утырган суган.

**СТРЕЛЬЧИ'ХА** *ж. разг. истор.* — стрелец хатыны, укчы хатыны.

**СТРЕ'ЛЯНЫЙ** — 1. атып үтерелгән, атып төшерелгән; *стреляная дичь* — атып төшерелгән киек кошлар; 2. *разг.* ут астында булган, сугышта булган; *стреляный солдат* — ут астында булган солдат; 3. атылган, атып файдаланылган; *стреляные гильзы* — атылган гильзалар. ◇ **Стреляный воробей** *разг.* — к. воробей.

**СТРЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. ату; *стрелять в птиц* — кошларга ату; 2. ату, ата белү; *он хорошо стреляет из винтовки и револьвера* — ул винтовкадан һәм револьвердан яхшы ата; 3. ату, атып алу; *журавлей стрелять трудно* — торналарны атып алуы кыен; 4. *простореч. вульг.* ату, сорап алу; *стрелять папиросы* — папирос ату; 5. *безл. разг.* чатнау; *стреляет в ухе* — колагым чатный. ◇ **Стрелять глазами** — 1. *разг. фам.* тиз-тиз карап алу, күз уйнату; 2. *простореч.* күз ату, (берәр нәрсәне) күз белән эзләү. **Стрелять из пушек по воробьям** *разг. ирон.* — ат белән чыпчык куу, күсәк белән черки куу, чебенне тупка тоту. **Стрелять холостыми зарядами** *перен. шутл.* — бушка эшләү; иләк белән су ташу.

**СТРЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* атылу, 2. атылу, үз-үзен ату, үз-үзен атып үтерү; 3. *устар.* атышу (дуэльдә).

**СТРЁМА: на стреме** (быть, стоять) *простореч.* — сакта тору; *на стрему* (ставить, идти) *простореч.* — сакка кую.

**СТРЕМГЛА'В** *нареч.* — бик тиз, атылып, уктай атылып.

**СТРЕМЁШКА** *ж. устар.* — к. штрипка.

**СТРЕМИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — ашкынучанлык, кызулык, тизлек.

**СТРЕМИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. ашкынулы, кызу, тиз; *стремительная речь* — кызу речь (ашкынып сөйләнгән речь); *стремительный поток* — тиз агым; 2. ашкынучан, кызу; ашыгучан, ашыгып эш итүчән; *стремительный человек* — ашыгучан кеше.

**СТРЁМИТЬ** *несов. простореч. вульг.* — сакта тору; сагалап тору.

**СТРЕМИ'ТЬ** *несов. поэт.* — юнәлдерү.

**СТРЕМИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *устар.* ашыгып бару, ашыгыч рәвештә юнәлү; 2. *книж.* омтылу, ашкыну, атлыгу; *я стремлюсь на юг* — мин җылы якка омтылам; 3. тырышу, омтылу.

**СТРЕМЛЕ'НИЕ** *ср.* — омтылыш; омтылу, ашкыну, атлыгу.

**СТРЕМНИ'НА** *ж. книж.* — 1. кызу агым, шәп агым; 2. текә яр, текә кыя, упкын.

**СТРЕМНИ'ННЫЙ** *книж.* — кызу агым ...-ы, шәп агым ...-ы; *стремнинные воды* — кызу агым сулары.

**СТРЕМИ'СТЫЙ** *книж. устар.* — текә, кыялы, кыя ташлы.

**СТРЕМОУ'ХИЙ** *устар. обл.* — сак колаклы, сизгер.

**СТРЕ'МЯ** *ср.* — 1. өзәңге; 2. *анат.* өзәңге сөяк (колакта); 3. *обл.* к. стремнина 1.

**СТРЕМЯ'НКА** *ж.* — 1. күчерелмәле баскыч (мәсәлән, бүлмәдә эшләгәндә кулланыла торган); 2. баудан ясалган асылмалы баскыч.

**СТРЕМЯННО'Й** *истор. редко* — к. стремянный 2.

**СТРЕМЯ'ННЫЙ** — 1. өзәңге ...-ы; *стремянный ремень* — өзәңге каешы; 2. *в знач. сущ. истор.* стремянный, менге атны каравчы ялчы; 3. *истор.* стремянный (Москва Русенда — патшаның тантаналы чыгышы вакытында гадәттә аның өзәңгесе янында торучы сарай хезмәтчесе).

**СТРЕНО'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. треножить.

**СТРЕНО'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — к. треножиться.

**СТРЕНО'ЖИТЬ** *сов.* — к. треножить.

**СТРЕ'ПЕТ** *м.* — сиртмә койрык (кош).

**СТРЕПЕТЁНОК** *м.* — сиртмә койрык баласы.

**СТРЕПЕТИ'НЫЙ** и *реже* **СТРЕПЕТО'ВЫЙ** — сиртмә койрык ...-ы; *стрепетиные гнёзда* — сиртмә койрык оялары.

**СТРЕПТОКО'КК** *м. мед., бакт.* — стрептококк (микробның бер төре).

**СТРЕПТОКО'ККОВЫЙ** *мед., бакт.* — стрептококк...-ы, стрептококклы; *стрептококковая ангина* — стрептококклы ангина.

**СТРЕПТОЦИ'Д** *м. мн. нет, мед.* — стрептоцид (дару).

**СТРЕ'СКАТЬ** *сов. простореч. вульг.* — тыгынып бетерү, бүсеп бетерү (мәсәлән, ипине).

**СТРЕХА'** *ж. спец.* — өй кыегы; өй кыегының чыгып тора торган өлеше, өй түбәсе.

**СТРЕЧО'К** *м.*: **задать** или **дать стречка** *разг. фам.* — к. стрекач.

**СТРИГА'ЛА** *м.* и *ж. спец.* — тиреләр чистартучы (күн производствосы эшчесе).

**СТРИГА'ЛЬНЫЙ** *тех.* — ворсны кырку...-ы, ворсны кыркып тигезләү...-ы; *стригальная машина* — ворс кырку машинасы.

**СТРИГА'ЛЬЩИК** *м.*, **СТРИГА'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.* — 1. ворс кырку машинасында эшләүче (текстиль промышленностенда); 2. сарык (куй, дөя) йоны кыркучы, сарык йоны алучы.

**СТРИГНУ'ТЬ** *однокр. разг.* — кисеп алу, кыркып алу.

**СТРИГО'ЛЬНИК** *м. истор.* — стригольник, стригольниклык тарафдары (сектант).

**СТРИГО'ЛЬНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *истор.* — стригольниклык (XIV гасырда борынгы Русьта, аеруча Новгород һәм Псков сәүдәгәрләре арасында, чиркәүләрдә реформалар үткәрүне таләп итүче сектантлык хәрәкәте).

**СТРИГУ'Н, СТРИГУНО'К** *м. спец.* — кырыкмыш (тай).

**СТРИГУ'ЩИЙ: стригущий лишай** *мед.* — тимрәү (чәчне койдыра торган тимрәү).

**СТРИЖ** *м.* — керәшә, яр карлыгачы.

**СТРИ'ЖЕНЫЙ** — 1. йоны алынган, йоны кыркылган; *стриженая овца* — йоны кыркылган сарык; 2. чәчен кырыктырган, чәчен кистергән, кыска чәчле; *стриженая женщина* — кыска чәчле хатын; 3. ботаклары киселгән, ботаклары кыркылган; *стриженые берёзки* — ботаклары киселгән каеннар.

**СТРИ'ЖКА** *ж. только ед.* — к. стричь.

**СТРИКТУ'РА** *ж. мед.* — стриктура (эчке органның кысылуы, тараюы).

**СТРИКУЛИ'СТ** *м.* — к. стрекулист.

**СТРИ'ППЕР** *м. с.-х.* — стриппер (урып-җыю машинасы).

**СТРИХНИ'Н** *м. мед. хим.* — стрихнин (бик көчле агу).

**СТРИЧЬ** *несов.* — 1. кырку, алу (чәч, йон, ворс турында), кисү (чәч, тырнак турында); *стричь волосы* — чәч кырку; *стричь овец* — сарыкларның йонын алу; 2. *разг.* кискәләү; *стричь бумагу* — кәгазь кискәләү; 3. *перен. простореч. фам.* тереләй талау. ◇ **Стричь всех под одну гребёнку** *перен.* — һәркемне бер аршынга үлчәү, һәркемне бер калыпка сугу.

**СТРИ'ЧЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* кыркылу, алыну, киселү; *волосы стригутся ножницами* — чәч кайчы белән кыркыла; 2. чәчне кырыктыру, чәчне кистерү, чәч алдыру; *стричься у парикмахера* — парикмахердан чәчне алдыру.

**СТРОГА'ЛЬ** *м. спец.* — струклаучы, ышкылаучы, струклап шомартучы.

**СТРОГА'ЛЬНЫЙ** *тех.* — струклау ...-ы, ышкылау ...-ы; *строгальный станок* — струклау станогы.

**СТРОГА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — к. строгаль.

**СТРОГА'ТЬ** *несов.* — струклау, ышкылау.

**СТРОГА'ТЬСЯ** *несов.* — струклану, ышкылану.

**СТРО'ГИЙ** — 1. таләпчән, таләп итүчән; кырыс; *строгий человек* — таләпчән кеше; 2. катгый, җитди; *строгий тон* — җитди тон; 3. бик каты, нык; *строгий порядок* — нык тәртип; 4. каты; *строгий выговор* — каты шелтә; 5. *спец.* каты, авырттыра торган; *строгий ошейник* — каты муенчак; 6. сизгер, сак; *строгая собака* — сизгер эт. ◇ **Строгое поведение** — үзенче әдәпле тоту.

**СТРОГНУ'ТЬ** *однокр. разг.* — струклап алу.

**СТРО'ГО** *нареч.* — 1. таләпчәнлек белән, таләпчәнлек күрсәтеп; *строго экзаменовать* — таләпчәнлек күрсәтеп имтихан кылу; 2. каты, нык; *строго наказать* — каты җәза бирү; 3. бик дөрес, төп-төгәл; *строго рассчитывать* — бик дөрес исәпләү; 4. жыйнак, гади; *строго одеваться* — гади киенү. ◇ **Строго-настрого** *разг.* — к. настрого.

**СТРО'ГОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* таләпчәнлек; 2. *только ед.* катылык, кырыслык, җитдилек; ныклык; 3. каты чара, каты тәртип; *введены большие строгости* — бик каты тәртип кертелгән.

**СТРОЕВИ'К** *м.* — строевик (строевой частьта хезмәт итүче).

**СТРОЕВО'Й** I — 1. строй ...-ы; строевой; *строевые части* — строевой частьлар; 2. *воен.* хәрби, гаскәри; *строевое седло* — хәрби ияр.

**СТРОЕВО'Й** II — төзү эшенә ярый торган, төзү эшенә китә торган (агач турында).

**СТРОЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. книж.* (*действие*) к. строить; 2. бина, корылма; каралты; *кирпичное строение* — кирпеч бина; 3. *чаще ед.* төзелеш; *строение земной коры* — җир кабыгының төзелеше.

**СТРО'ЖКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. строгать.

**СТРОИ'ТЕЛЬ** *м.* — 1. ... салучы; төзүче; *строитель школы* — мәктәп салучы; *строители социализма* — социализм төзүчеләр; 2. *церк.* строитель (кайбер монастырьлар башлыгының исеме).

**СТРОИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. төзү ...-ы; төзе-

леш ...-ы; *строительные материалы* — төзү материаллары; 2. төзелештә эшләүче..., төзү эшләрендә эшләүче; *строительные рабочие* — төзелештә эшләүче эшчеләр; 3. *перен. книж.* (*созидательный*) иҗади.

**СТРОИ'ТЕЛЬСТВО** *ср.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. строить 1; 2. төзү эшләре, төзелеш, корылыш; *работать на строительстве* — төзү эшләрендә эшләү; *гидротехнические строительства* — гидротехник төзелешләр; 3. *только ед. перен.* төзелеш; *социалистическое строительство* — социалистик төзелеш.

**СТРО'ИТЬ** *несов.* — 1. төзү, салу, кору; *строить дом* — йорт салу; 2. төзү, ясау; *строить планы на точных данных* — планнарны төгәл мәгълүматларга нигезләп төзү; 3. *мат.* сызу; *строить треугольник* — өчпочмак сызу; 4. *воен.* (сафка) тезү; *строить полк* — полкны сафка тезү; 5. *спец.* тегү, тегеп хәзерләү; *строить сапоги* — күн итекләр тегү; 6. *редко* көйләү; *ай, ребята, пойте* — *только гусли стройте* — әй, егетләр, җырлагыз — гөсләләрне көйләгез (көйгә салыгыз); 7. *спец.* көйгә салыну; *кларнет из плохого материала совсем не строит* — начар материалдан ясалган кларнет бөтенләй көйгә салынмый. ◇ **Строить глазки** — күз уйнату, каш сикертү-күз уйнату. **Строить дурака из** *кого-н.* — (берәр кешене) ахмак итеп күрсәтү, тиле итеп күрсәтү.

**СТРОИ'ТЬ** *сов.* — 1. өч катлау, өчәрләү, өч катлы итү (мәсәлән, җепне); 2. (җирне) өченче кат сөрү.

**СТРО'ИТЬСЯ** *несов.* — 1. (үзенә) йорт салу; (үзенә) каралты салу; 2. *воен.* сафка тезелү; 3. *страд.* төзелү, салыну; 4. *страд.* төзелү, корылу, ясалу; 5. *страд. мат.* сызылу.

**СТРОЙ** *м.* — 1. *устар., обл.* рәт; як; *деревенская улица в два строя* — ике яклы авыл урамы; 2. рәт, саф; *стоять в строю* — сафта тору; 3. саф, строй; *вступают в строй новые заводы* — яңа заводлар сафка керә (төзелә); *выбыл из строя по ранению* — яралану сәбәпле сафтан чыкты; 4. строй; төзелеш; *социалистический строй* — социалистик строй; 5. *муз.* көйләнеш; 6. *только ед. перен.* аһәңлелек, гармония. ◇ **Выйти** (выбыть) **из строя** — сафтан чыгу, яраксыз хәлгә килү. **Вывести из строя** — сафтан чыгару, яраксыз хәлгә китерү.

**СТРО'ЙКА** *ж.* — 1. *только ед. разг.* (*действие*) к. строить 1; 2. төзелеш; төзү; *работать на стройке* — төзелештә эшләү; 3. *простореч.* корылма; *новая стройка* — яңа корылма.

**СТРО'ЙНОСТЬ** *м. мн нет* — 1. зифалык, сылулык, зифа буйлылык; 2. тигезлек, төзеклек; 3. гармониялелек, аһәңлелек.

**СТРО'ЙНЫЙ** — 1. зифа, сылу, зифа буйлы; *стройная девушка* — зифа буйлы кыз; 2. тигез, төзек; *стройные ряды демонстрантов* — демонстрантларның тигез сафлары; 3. гармонияле, төзек, аһәңле, матур итеп ...; *стройное пение* — матур итеп җырлау.

**СТРОКА'** *ж.* — 1. юл; 2. сызык (язуда). ◇ **Между строк читать** — тел төбе кая барганын (ягъни авторның бу сүзләре астында нәрсә яшерелгәнен) төшенү, төшенеп уку. **Строка в строку** (пересказать, списать и. т. п.) — сүзгә сүз; сүзмә-сүз; бер сүзен дә төшереп калдырмыйча (сөйләп бирү, күчереп язып алу һ. б.).

**СТРОКУЛИ'СТ** *м. простореч.* — стрекулист.

**СТРО'НУТЬ** *сов. разг.* — кузгату, кузгатып җибәрү; *стронуть с места* — урыныннан кузгату.

**СТРО'НУТЬСЯ** *сов. разг.* — кузгалу, кузгалып китү; *еле стронулся с места* — көчхәл белән урыныннан кузгалды.

**СТРО'НЦИЙ** *м. мн.* нет, *хим.* — стронций (саргылт төстәге бик җиңел металл).

**СТРОП** *м. спец. мор., ав.* — строп (йөкне йөк күтәрү кранына, гондоланы дирижабльгә яки аэростатка бәйләү өчен һәм парашютистның парашютка асылынып төшүе өчен ясалган бау, аркан яки трос).

**СТРОПИ'ЛИНА** *ж. разг.* — атламаның (бәпкәнең, кайчының) бер борысы, бер агачы.

**СТРОПИ'ЛИТЬ** *несов. спец.* — атламалар (бәпкәләр, кайчылар) кую; *стропилить дом* — өйгә бәпкәләр кую.

**СТРОПИ'ЛО** *ср.* — атлама, бәпкә, кайчы.

**СТРОПТИ'ВЕТЬ** *несов. разг.* — киреләнү, тискәреләнү, үзсүзләнү.

**СТРОПТИ'ВЕЦ** *м.*, **СТРОПТИ'ВИЦА** *ж. разг.* — кире кеше, тискәре кеше, үзсүзле кеше.

**СТРОПТИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — кирелек, тискәрелек, үзсүзлелек.

**СТРОПТИ'ВЫЙ** *разг.* — кире, тискәре, үзсүзле.

**СТРОСТИ'ТЬ** *сов. тех., обл.* — к. тростить.

**СТРОФА'** *ж. лит.* — строфа (шигырьнең берничә юлдан торган бүлеге).

**СТРОФА'НТ** *м. мн. нет* — строфант (1. *бот.* тропик үсемлек; 2. *мед.* шул үсемлекнең орлыгыннан әзерләнгән һәм медицинада йөрәк авыруларын дәвалауда кулланыла торган төнәтмә).

**СТРО'ФИКА** *ж. мн.* нет, *лит.* — строфика (1. шигырьне строфаларга бүлү; 2. шигырь төзелеше турындагы фәннең строфалар төзелешен өйрәнә торган бүлеге).

**СТРОФИ'ЧЕСКИЙ** *лит.* — строфалы, строфаларга бүленгән.

**СТРОЧЁНЫЙ** — каелган, каеп чыгылган, буйлап тегелгән.

**СТРОЧИ'ЛА** *м.* и *ж. разг. шутл.* — күп язучы.

**СТРОЧИ'ТЬ** *несов.* — 1. каю, буйлап тегү; *строчить рукава* — җиңнәрне каю; 2. *перен. разг. шутл. ирон.* язу; *строчить письмо* — хат язу.

**СТРОЧИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — каелу, буйлап тегелү.

**СТРО'ЧКА** I *ж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. строчить 1; 2. җөй; *мелкая строчка* — вак җөй.

**СТРО'ЧКА** II *ж.* — юл (китапта, язуда). ◇ **Строчка в строчку** — к. строка.

**СТРОЧНО'Й** и **СТРО'ЧНЫЙ**: **строчная буква** — юл хәрефе (язуда, басмада).

**СТРОЧО'К** *м.* — кәҗә гөмбәсе.

**СТРУБЦИ'НА** и **СТРУБЦИ'НКА** *ж. тех. стол.* — струбцина, винтлы кыстыргыч.

**СТРУГ** I *м.* — ышкы, струг (1. *спец.* рубанок, фуганок кебек инструментларның гомуми атамасы; 2. *тех.* юл тигезләү машинасы).

**СТРУГ** II *м. обл. старин.* — агач көймә, каек.

**СТРУГОВЩИ'К** *м. обл.* — көймәче, каекчы (көймә хуҗасы яки көймәдә эшләүче).

**СТРУЖИ'ТЬ** *несов. плот.* — ышкылау, струклау.

**СТРУ'ЖКА** *ж.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. стружить; 2. *собир.* йомычка; стружка.

**СТРУИ'СТЫЙ** *поэт.* — каты ага торган, тиз ага торган, агкын.

**СТРУИ'ТЬ** *несов. книж. поэт.* — агызу, тарату, чәчү, сибү.

**СТРУИ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — (сузылып-сузылып) агу.

**СТРУ'ЙКА** *ж.* — к. струя.

**СТРУ'ЙЧАТЫЙ** *спец.* — буй-буй, дулкынсыман сызыклы.

**СТРУКТУ'РА** *ж.* — структура, төзелеш.

**СТРУКТУ'РНЫЙ** — структура ...-ы, төзелеш ...-ы; *структурный состав слова* — сүзнең структура составы.

**СТРУНА'** *ж.* — 1. кыл (музыка коралларында); 2. кереш, җәя бавы (гомумән берәр нәрсәне тарттырып бәйләгән бау, җеп, кыл). ◇ **Спинная струна** — к. хорда 2. **Слабая струна** *чья-н.* — (кешенең) нечкә кылы, йомшак ягы.

**СТРУ'НИТЬ** *несов. охот. спец.* — каеш белән бәйләү (ауда тотылган хайванның борынын).

**СТРУ'НИТЬСЯ** *несов. страд. охот. спец.* — каеш белән бәйләп куелу (ауда тотылган хайванның борыны турында).

**СТРУ'НКА** *ж.* — к. струна. ◇ **В струнку** (вытянуться, стать) — шәм кебек катып (калу), туп-туры басып (тору). **По струнке ходить** *разг.* — (берәр кеше) каршында биеп йөрү, песи булып йөрү.

**СТРУ'ННИК** *м.* — кыллы музыка коралында уйнаучы.

**СТРУ'ННЫЙ** — 1. кыллы; *струнные инструменты бывают щипковые, клавишные и смычковые* — кыллы музыка коралларычиертеп уйнала торган, телле һәм смычоклы булалар; 2. кыллы музыка кораллары ...-ы; *струнный оркестр* — кыллы музыка кораллары оркестры.

**СТРУП** *м.* — кутыр (төзәлеп килә торган яра өстендә була).

**СТРУ'СИТЬ** *сов.* — куркып калу, шүрләп калу.

**СТРУСИ'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. селкеп кушу, селкеп аралаштыру; 2. селкеп кою; селкеп коеп төшерү.

**СТРУСИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. селкенеп кушылу, селкенеп аралашу; 2. селкенеп коелу.

**СТРУХНУ'ТЬ** *сов. разг.* — к. стру́сить.

**СТРУЧКОВА'ТЫЙ** — кузаксыман.

**СТРУЧКО'ВЫЙ** — кузаклы.

**СТРУЧО'К** *м.* — кузак.

**СТРУ'ЧЬЯ** *мн.* — кузаклар.

**СТРУ'ШИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. струсить.

**СТРУ'ШИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. струситься.

**СТРУЯ'** *ж.* — 1. агынты, агым (су, һава, пар, газ, нур агынтысы); *воздушная струя* — һава агымы; 2. *спец.* дулкынсыман буй (тукымада, обойда); 3. *перен. книж. поэт.* су, сулар.

**СТРЮ'ЦКИЙ** *м. простореч. презрит.* — буш кеше, түбән кеше.

**СТРЯ'ПАТЬ** *несов.* — 1. (аш-су) пешерү, пешеренү; *стряпать обед* — төшке аш пешерү; 2. *перен. разг. фам. пренебр.* (берәр нәрсә) ясау, маташтыру.

**СТРЯ'ПАТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* пешерелү (аш-су турында); 2. *обл.* к. стряпать 1.

**СТРЯ'ПКА** *ж. обл.* — к. стряпуха.

**СТРЯПНЯ'** *ж. мн.* нет — 1. (*действие*) к. стряпать; 2. *разг. фам.* аш-су.

**СТРЯПУ'ХА** *ж. простореч.* — аш пешерүче, пешерүче, кухарка.

**СТРЯПУ'ЩАЯ** *ж. простореч. устар.* — кухня, аш пешерә торган урын, аш хәзерли торган урын.

**СТРЯ'ПЧЕСКИЙ** *истор. дореВол.* — стряпчий ...-ы; *стряпческие обязанности* — стряпчий вазифалары.

**СТРЯ'ПЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *истор, дореВол.* — стряпчийлык.

**СТРЯ'ПЧИЙ** *м.* — стряпчий (1. *истор.* Москва Русенда: патша сараенда хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгән хезмәтче; 2. *истор.* суд учреждениеләрендә суд эшләрен алып бару тәртибен күзәтүче чиновник; 3. *дореВол.* ходатай, хосусый вәкил).

**СТРЯСА'ТЬ** *несов.* — к. стрясти.

**СТРЯСА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. стрястись; 2. *страд.* селкеп төшерелү, кагып төшерелү; селкеп коелу; 3. *страд.* селкетеп катнаштырылу.

**СТРЯСТИ'** *сов.* — 1. селкеп төшерү, кагып төшерү; *стрясти пыль с ног* — аяклардан тузанны кагып төшерү; 2. селкетеп кою, селкетеп төшерү; *стрясти яблоки с дерева* — алмагачларны селкетеп алма кою; 3. *простореч.* селкетеп катнаштыру, селкетеп аралаштыру.

**СТРЯСТИ'СЬ** *сов.* — 1. *разг.* булу, килеп чыгу (көтелмәгән нәрсә, күңелсез хәл турында); *беда стряслась* — бәла килеп чыкты; *что с тобой стряслось?* — сиңа ни булды? 2. *простореч.* селкенеп кушылу; селкенеп катнашу, селкенеп аралашу, селкенә-селкенә катнашу, селкенеп катнашып бетү; *мука и соль стряслись дорогой* — юлда он белән тоз селкенеп кушылганнар.

**СТРЯХА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. стряхнуть.

**СТРЯХА'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. стряхнуться; 2. *страд.* к. стряхиваться 2.

**СТРЯ'ХИВАТЬ** *несов.* — к. стряхнуть.

**СТРЯ'ХИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. стряхнуться; 2. *страд.* кагып төшерелү, селкеп төшерелү.

**СТРЯХНУ'ТЬ** *сов.* — 1. кагып төшерү, селкеп төшерү; *стряхнуть пылинку с платья* — күлмәктән тузанны кагып төшерү; 2. *перен.* котылу, бер читкә ташлау; *стряхнуть с себя тяжёлые мысли* — авыр уйлардан котылу.

**СТРЯХНУ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — төшү, коелып төшү.

**СТУДЕНЕ'ТЬ** *несов.* — койкалану; ою.

**СТУДЕНИ'СТЫЙ** — койкасыман.

**СТУДЕНИ'ТЬСЯ** *несов.* — к. студенеть.

**СТУДЕ'НТ** *м.* — студент.

**СТУДЕ'НТКА** *ж.* — студентка.

**СТУДЕ'НЧЕСКИЙ** — студент ...-ы, студентлар ...-ы; *студенческая библиотека* — студентлар китапханәсе.

**СТУДЕ'НЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — 1. студентлар; 2. студентлык еллары.

**СТУДЁНЫЙ** *простореч.* — бик салкын, бик суык.

**СТУ'ДЕНЬ** *м.* — койка́. ◇ **Студень говяжий** — сыер баш-аягы (ягъни ит түшкәсенең койка ясауга китә торган өлеше).

**СТУДИ'ЕЦ** *м.* — студия укучысы, студиядә укучы.

**СТУДИО'З, СТУДИО'ЗУС** *м. разг. шутл. устар.* — студиоз, студент.

**СТУДИ'ТЬ** *несов. разг.* — суыту, суындыру.

**СТУДИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *простореч.* суыну; 2. *страд. разг.* суытылу.

**СТУ'ДИЯ** *ж.* — студия 1. (художникның, скульпторның мастерское, эш бүлмәсе; 2. сынлы сәнгать, эвәләп ясау, музыка, балет мәктәбе яки классы; 3. театр сәнгате өлкәсендә яшь кадрлар хәзерләү белән шөгыльләнүче театр коллективы).

**СТУ'ЖА** *ж. мн.* нет — каты суык, чатлама суык.

**СТУК** I *м.* — 1. шакылдау, шакылдаган тавыш, шакылдату, шакылдаткан тавыш; дыңгырдау, дыңгырдаган тавыш, дыңгырдату, дыңгырдаткан тавыш; *стук телеги* — арба дыңгырдаган тавыш; 2. *разг.* кагу, тибү; *стуки сердца* — йөрәк тибүе.

**СТУК** II *м. разг.* — 1. *в знач. сказ.* шак итеп сукты, шап итеп сукты; *он стук кулаком в дверь* — ул йодрыгы белән шак итеп ишеккә сукты; 2. тук; *стук... стук... стук!.. Теглев тотчас выпрямился и начал слушать* (Тургенев) — тук... тук... тук!.. Теглев шунда ук турайды да тынлый башлады.

**СТУ'КАТЬ** *несов.* — 1. к. стукнуть 1, 2, 3; 2. *разг. фам.* шакылдату (язу машинкасында басу).

**СТУ'КАТЬСЯ** *несов.* — к. стукнуться.

**СТУ'КНУТЬ** *сов.* — 1. сугу, сугып җибәрү, кундырып алу; *стукнуть кулаком по спине* — аркага йодрык белән сугу; 2. шак итеп сугу, шап итеп сугу; *кто-то стукнул в дверь* — кемдер ишеккә шак итеп сукты; 3. *простореч. вульг. (убить)* сугып үтерү; 4. *разг. фам. (выпить)* эчү, төшерү; 5. *безл. разг. фам.* тулу; *тридцать лет стукнуло* — утыз яшь тулды.

**СТУ'КНУТЬСЯ** *сов.* — бәрелү; бәрелешү.

**СТУКОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *разг.* — шакылдаган тавыш, шакылдаткан тавыш.

**СТУЛ** *м.* — урындык, утыргыч. ◇ **У больного сегодня не было стула** *мед.* — авыру бүген тышка чыкмады.

**СТУЛЬЧА'К** *м.* — олы тәрәт урындыгы (балалар, авырулар өчен), бәдрәф утыргычы.

**СТУ'ПА** *ж.* — киле. ◇ **В ступе воду толочь** — юкны бушка аудару, иләк белән су ташу.

**СТУПА'ТЬ** *несов.* — атлау. ◇ **Ступай(те)** *повел. накл.* — бар(ыгыз), кит(егез).

**СТУПЕ'НЧАТЫЙ** — буынлы, баскычлы баскыч-баскыч, киртләч-киртләч.

**СТУПЕ'НЬ** *ж.* — 1. баскыч, басма; 2. киртләч; 3. *перен.* баскыч, дәрәҗә; 4. буын.

**СТУПИ'ТЬ** *сов.* — 1. атлау, аяк атлау; 2. *разг.* к. наступать 1 в 1 знач.

**СТУПИ'ЦА** *ж.* — бүкән (тәгәрмәч бүкәне).

**СТУ'ПКА** *ж.* — к. ступа.

**СТУПНЯ'** *ж.* — к. стопа 1.

**СТУ'ПОР** *м. мн.* нет, *мед.* — ступор (авыр психик авыруларның бер күренеше — катып калу).

**СТУ'ХНУТЬ** *сов. обл.* — сүнү, басылу.

**СТУЧА'ТЬ** *несов.* — 1. шаку, кагу, шакылдау, шакылдату; *стучать в дверь* — ишек шакылдату; 2. тибү, дөп-дөп итү; чатнау; *стучит в висках* — чигәләрем чатный. ◇ **Зубы стучат** — тешләре шык-шык итә.

**СТУЧА'ТЬСЯ** *несов.* — шаку, кагу, шакылдату. ◇ **Стучаться в двери** *перен.* — якынлашып килү. **Стучаться** (ломиться) **в открытую дверь** — к. дверь.

**СТУШЕВА'ТЬ** *сов.* — 1. *спец.* күләгә ясау, күләгәләү; 2. *перен. разг. редко (заставить удалиться)* китәргә мәҗбүр итү, куып җибәрү.

**СТУШЕВА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *спец.* күләгә ясалу; 2. *перен. разг. (незаметно удалиться)* сиздермичә генә китү, сиздерми генә таю (шылу); 3. *перен. простореч.* аптырап калу, каушап калу, каушап китү; *стушевался на экзамене* — имтихан биргәндә каушап калдым.

**СТУШЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. стушевать.

**СТУШЁВЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. стушеваться.

**СТУШО'ВКА** *ж. спец.* — 1. *только ед. (действие)* к. стушевать 1; 2. күләгә ясалган урын (җир).

**СТЫД** *м. мн.* нет — 1. оят, оялу; *покраснеть со стыда* — оялудан кызару; 2. оят, хурлык; *стыд пал на седую голову мою* — минем карт башым хурлыкка калды; 3. *простореч.* к. срам 2.

**СТЫДИ'ТЬ** *несов.* — оялту.

**СТЫДИ'ТЬСЯ** *несов.* — оялу.

**СТЫДЛИ'ВЕЦ** *м.*, **СТЫДЛИ'ВИЦА** *ж. устар.* — оялучан кеше, оялчан кеше.

**СТЫДЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — оялу(чанлык), оялчанлык.

**СТЫДЛИ'ВЫЙ** — оялучан, оялчан.

◇ Стыдливый кусок — тәлинкәдә калган соңгы кисәк.

**СТЫ'ДНО** *в знач. сказ.* — оят.

**СТЫ'ДНЫЙ** — оялта торган, оялткыч, оялырлык, хурландыра торган, хурлыклы.

**СТЫДО'БА, СТЫДО'БУШКА** *ж. мн.* нет, *обл. нар.-поэт.* — к. стыд 1, 2.

**СТЫК** *м.* — (берәр нәрсәнең) ялганган урыны, беркетелгән урыны, тоташкан урыны, тоташтырылган урыны.

**СТЫКА'ТЬ** *несов.* — (берсенең очына икенчесен) ялгау, беркетү, тоташтыру.

**СТЫКОВА'ТЬ** *несов. спец.* — к. стыкать.

**СТЫКОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — ялгану, беркетелү, тоташтырылу.

**СТЫКОВО'Й** *спец.* — ялганган (беркетелгән, тоташтырылган, тоташкан) урынындагы.

**СТЫ'ЛЫЙ** *обл.* — салкын, суынган.

**СТЫ'НУТЬ** *несов.* — к. стыть.

**СТЫ'РИТЬ** *сов. простореч. вульг.* — к. тырить.

**СТЫТЬ** *несов.* — **1.** суыну; *суп стынет* — аш суына; **2.** *простореч.* туңу, кату, бозлану; *на дворе вода стынет* — ишек алдында су ката.

**СТЫ'ЧКА** *ж.* — **1.** *обл.* к. стык; **2.** *разг.* к. столкновение.

**СТЯГ** I *м.* — **1.** *обл. (шест, жердина)* колга, киртә; **2.** *книж. поэт.* и *ритор. (знамя)* байрак, әләм.

**СТЯГ** II *м. обл. старин.* — түшкә, ит түшкәсе.

**СТЯГА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. стягивать.

**СТЯ'ГИВАТЬ** *несов.* — к. стянуть 1, 2, 3, 4, 5.

**СТЯ'ГИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. стянуться; **2.** *страд.* тартып (кысып) бәйләнү, тартып бәйләп куелу; **3.** *страд.* бер урынга җыелу, тупланылу; **4.** *страд.* тартып алыну, тартып төшерелү.

**СТЯЖА'НИЕ** *ср. книж. ритор.* — **1.** *(действие)* к. стяжать; **2.** *старин.* мал, мал-мөлкәт.

**СТЯЖА'ТЕЛЬ** *м. книж. ритор.* — **1.** байлык җыючы, мал җыючы (кеше); **2.** *презрит.* карун, комсызланып мал җыючы.

**СТЯЖА'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. ритор.* — **1.** *устар.* мал җыючан, байлык җыючан; **2.** *презрит.* карун..., комсыз.

**СТЯЖА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — казану, ирешү, ия булу; *стяжать славу* — дан казану.

**СТЯЖА'ТЬСЯ** *несов. страд. книж. ритор.* — казанылу, ирешелү.

**СТЯЖНО'Й** *спец.* — тартып бәйләнә торган.

**СТЯНУ'ТЬ** *сов.* — **1.** *(сжимая, туго связать)* тартып бәйләү, тартып бәйләп кую, тартып кысып бәйләү; (билне) кысып буу; **2.** *(собрать в одно место)* бер урынга җыю, туплау; **3.** *мат.* очларын тоташтыру; *дуга стянута хордой* — дуганың очлары хорда белән тоташтырылган; **4.** *безл. простореч.* тартышу; *руку стянуло* — кулым тартышты; **5.** тартып алу, тартып төшерү; тартып чыгару; *стянуть со спящего одеяло* — йоклап яткан кешенең өстеннән юрганын тартып алу; *стянуть шалуна с забора* — шаян малайны коймадан тартып төшерү; **6.** *разг.* чәлдерү (урлау мәгънәсендә).

**СТЯНУ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** *разг.* кыскару, утыру; *верёвка от сырости стянулась* — бау юешләнеп кыскарган; **2.** *разг.* билне кысып буу; *стянуться кушаком* — билне кушак белән кысып буу; **3.** (бер җиргә) җыелу, туплану; *войска стянулись к переправам* — гаскәрләр елгадан кичү урыннарына тупландылар.

**СУ** *ср. нескл.* — су (Франциядә вак акча).

**СУБАРЕ'НДА** *ж. мн.* нет, *право* — субаренда (үзе арендага алып тоткан милекне башка бер кешегә арендага бирү).

**СУБАРКТИ'ЧЕСКИЙ** *геогр.* — субарктик, Арктика янындагы, Арктика тирәсендәге.

**СУББО'ТА** *ж.* — шимбә (көн).

**СУББО'ТНИЙ** — шимбә...; *день субботний* — шимбә көн.

**СУББО'ТНИК** *м.* — өмә, шимбә өмәсе, субботник.

**СУБЛИМА'Т** *м. хим.* — сублимат, сублимация продукты.

**СУБЛИМА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — сублимация (җылыту нәтиҗәсендә каты матдәнең сыеклыкка әйләнмичә турыдан-туры газга әверелүе).

**СУБЛИМИ'РОВАТЬ** *несов. хим.* — сублимация ясау (каты матдәне җылытып, турыдан-туры газга әвереллдерү).

**СУБЛИМИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. хим.* — сублимация ясалу, газга әверелдерелү.

**СУБМАРИ'НА** *ж. устар.* — су асты көймәсе.

**СУБОРДИНА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — субординация (хезмәттә түбән чиннарның югары чиннарга буйсынуы).

**СУБРЕ'ТКА** *ж. лит. театр.* — субретка (борынгы комедия һәм водевильләрнең персонажы — шат күңелле хәйләкәр кыз).

**СУБСИДИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — акчалата ярдәм күрсәтү, субсидия бирү.

**СУБСИДИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — акчалата ярдәм күрсәтелү, субсидия бирелү.

**СУБСИ'ДИЯ** *ж.* — субсидия, акчалата ярдәм.

**СУБСТАНТИВА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *лингв.* — субстантивлашу, исемгә әверелү; субстантивлаштыру, исемгә әверелдерү.

**СУБСТАНТИВИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. лингв.* — субстантивлаштыру, исемгә әверелдерү.

**СУБСТАНТИВИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. лингв.* — субстантивлашу, исемгә әверелү.

**СУБСТАНТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *лингв.* — субстантивлык.

**СУБСТАНТИ'ВНЫЙ** I *лингв.* — субстантив.

**СУБСТАНТИ'ВНЫЙ** II *спец.* — мөстәкыйль.

**СУБСТАНЦИОНАЛИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. филос. науч.* — субстанцияләштерү, субстанция итеп күз алдына китерү.

**СУБСТАНЦИОНАЛИЗИ'РОВАТЬСЯ** *филос. науч.* — **1.** *сов.* и *несов.* субстанциялә-

итү, субстанциягә әверелү; 2. *несов. страд.* субстанцияләштерелү.

**СУБСТАНЦИОНА'ЛЬНЫЙ** *филос. науч.*— субстанциональ.

**СУБСТА'НЦИЯ** *ж.*— субстанция (1. *филос.* барлык күренешләрнең нигезе булырак мәңге хәрәкәт итә һәм үзгәрә торган материя; 2. *науч.* берәр нәрсәнең нигезе, асылы, төп җирлеге).

**СУБСТИТУ'Т** *м. науч. спец.*— субститут (берәр нәрсәне, күренешне, матдәне алмаштыручы икенче бер нәрсә, күренеш, матдә).

**СУБСТИТУ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *науч. спец.*— субституция (берәр нәрсәне функциональ яктан аңа охшаш булган икенче бер нәрсә белән алмаштыру, мәсәлән, бер металлны икенче бер металл белән, телдәге бер авазны икенче бер аваз белән һ. б.).

**СУБСТРА'Т** *м.*— субстрат (1. *филос. науч.* күренешләрнең нигезе; 2. *биол.* микроблар үрчеткеч азыклы тирәлек, среда).

**СУБСТРАТОСТА'Т** *м. ав.*— субстратостат (стратосфераның түбәнге катламнарында очу өчен аэростат).

**СУБТИ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— нечкәлек, нәзеклек, нәфислек.

**СУБТИ'ЛЬНЫЙ** *разг.*— нечкә, нәзек, нәфис.

**СУБТРО'ПИКИ** *ед.* нет, *геогр.*— субтропиклар(тропикка якын өлкәләр).

**СУБТРОПИ'ЧЕСКИЙ** *геогр.*— субтропик; тропикка якын, тропик тирәсендәге.

**СУБЪЕ'КТ** *м.*— 1. *грам.* субъект, ия; 2. *филос.* субъект, шәхес; *объект существует независимо от субъекта* — объект субъекттан тыш яши; 3. субъект (логикада фикер йөртү предметы); 4. *мед., право* субъект, шәхес, кеше, зат; *болезненный субъект* — авыручан кеше; *субъект права* — хокук субъекты; 5. *разг.* субъект, бәндә, кеше; *подозрительный субъект* — шикле кеше.

**СУБЪЕКТИВИ'ЗМ** *м. мн.* нет — субъективизм (1. *филос.* объектив чынбарлыкны инкарь итүче һәм тышкы дөнья субъект аңының продукты гына ул дип раслаучы идеалистик юнәлеш; 2. *социол.* сыйнфый җәмгыятьнең үсеше экономик үсеш һәм сыйнфый көрәш законнарына түгел, бәлки идеяләргә һәм аерым күренекле шәхесләргә бәйләнгән дип раслаучы буржуаз социологик юнәлеш; 3. *книж.* к. субъективность).

**СУБЪЕКТИВИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. филос. социол.*— субъективизм ноктасыннан чыгып эш итү.

**СУБЪЕКТИВИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. филос. социол.*— субъективизм ноктасыннан чыгып эш ителү.

**СУБЪЕКТИВИ'СТ** *м. книж.*— субъективист, субъективизм тарафдары.

**СУБЪЕКТИВИСТИ'ЧЕСКИЙ, СУБЪЕКТИВИ'СТСКИЙ** *книж.*— субъективистик.

**СУБЪЕКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. субъективлык; 2. субъективлык, берьяклылык.

**СУБЪЕКТИ'ВНЫЙ** *книж.*— 1. субъектив, шәхси; *субъективные переживания* — субъектив кичерешләр; 2. субъектив, берьяклы; *субъективный взгляд* — субъектив караш. ◇ **Субъективный идеализм** — к. субъективизм 1.

**СУВЕНИ'Р** *м.*— сувенир, бүләк, истәлек, ядкәр.

**СУВЕРЕ'Н** *м. полит., право, истор.*— суверен (югары власть башындагы кеше).

**СУВЕРЕНИТЕ'Т** *м. мн.* нет, *полит.*— суверенитет (1. *право* сувереннын хокуклары, югары властьның хокуклары; 2. дәүләтнең эчке һәм тышкы эшләрдә тулы мөстәкыйльлеге).

**СУВЕРЕ'ННЫЙ** *полит. право* — 1. суверен ..., мөстәкыйль, бәйсез; *суверенный народ*—мөстәкыйль халык; 2. суверенлык...-ы, бәйсезлек...-ы; *СССР охраняет суверенные права союзных республик* (Конституция СССР) — СССР союздаш республикаларның суверенлык хокукларын саклый.

**СУВО'Й** *м. обл.*— 1. бөтерелгән нәрсә, чорнап куелган нәрсә; 2. *собир. спец.* агачның бормаланып үскән катламнары; 3. көрт.

**СУГЛИ'НИСТЫЙ** — балчыклы.

**СУГЛИ'НОК** *м. мн.* нет — балчыклы туфрак.

**СУГОЛО'ВНЫЙ** *спец. ж.*: **суголовный ремень** — (йөгәннең) яңак каешы.

**СУГОЛО'ВЬЕ** *ср. спец.*—1. йөгәннең яңак каешы; 2. йөгән.

**СУГРО'Б** *м.*— көрт.

**СУГРО'БИСТЫЙ** *разг.*— көртле.

**СУГУ'БЫЙ** — 1. *книж. устар.* икеләтә, ике тапкыр артык, ике тапкыр күбрәк, ике мәртәбә; 2. *перен.* аеруча зур, аеруча көчле; *оказать сугубое внимание* — аеруча зур игътибар күрсәтү.

**СУД** *м.*— 1. хөкем; *отдать на суд кому-н.* — (берәр кешенең) хөкеменә бирү; 2. суд; *военный суд* — хәрби суд; *отдать под суд* — судка бирү; 3. *только ед. собир.* суд, судьялар; *суд идёт* — суд килә. ◇ **Страшный суд** *религ.*— мәхшәр көне, кыямәт көне. **Пока суд да дело** *разг.* — ул-бу булганчы, ул-бу булган арада. **Суда нет** — гаепләп булмый.

**СУДА'** *нареч. простореч.*— к. сюда.

**СУДА'К** *м.*— судак (балык).

**СУДАКО'ВИНА** *ж. мн.* нет, *простореч.*— судак ите.

**СУДАКО'ВЫЙ** — судак ...-ы, судак балыгыннан пешерелгән; *судаковая уха*—судак шулпасы.

**СУДА'РИК** *м. простореч. фам. устар.*— 1. әфәндекәй; 2. к. любовник 1, 2; 3. *пренебр.* к. сударь.

**СУДА'РКА** *ж. простореч. устар.*— к. любовница.

**СУДА'РЫНЯ** *ж. устар.*— ханым.

**СУ'ДАРЬ** *м. устар.*— әфәнде.

**СУДА'ЧИЙ** — к. судаковый.

**СУДА'ЧИТЬ** *несов. разг. фам.* — ләчтит сату, лыгыр сату, суган сату, гайбәт сату.

**СУДЕ'БНИК** *м. истор.*—судебник (законнар һәм карарлар җыентыгы).

**СУДЕ'БНЫЙ** — суд ...-ы; *судебный про-*

*цесс* — суд процессы; *судебное решение* — суд карары. ◇ **Судебные установления** *офиц. устар.* — суд органнары (системасы).

**СУДЕ'ЙСКАЯ** *ж. в знач. сущ.* — судьялар бүлмәсе.

**СУДЕ'ЙСКИЙ** — судья ...-ы, судьялар ...-ы; *судейское место* — судья урыны; *судейское сословие (доревол.)* — судьялар сословиесе; *судейский свисток (спорт.)* — судья свистогы.

**СУДЕ'ЙСТВО** *ср. мн.* нет, *спорт.* — судьялык, судьялык итү.

**СУДЁНЫШКО** *ср. разг.* — судно кисәге, кечкенә судно.

**СУДИ'ЛИЩЕ** *ср. книж. ритор. устар.* или *презрит.* — суд, суд утырышы.

**СУДИ'МОСТЬ** *ж. право* — хөкем астында булу, хөкем астында булганлык.

**СУДИ'ТЬ** *несов.* — **1.** фикер йөртү, хөкем кылу, хөкем йөртү; уйлау; *судить по внешнему виду о здоровье* — тышкы кыяфәткә карап сәламәтлек турында хөкем йөртү; **2.** суд ясау, хөкем итү; *судить преступника* — җинаятьчене хөкем итү; **3.** гаепләү; *не судите его строго* — аны каты гаепләмәгез; **4.** *спорт.* судьялык итү, судья вазифасын үтәү; **5.** *преимущ. в краткой ф-ме прич.* язу, насыйп булу; насыйп итү; *мне суждено было встретиться с ним ещё раз* — миңа тагы бер тапкыр аның белән очрашырга насыйп булды. ◇ **Суди(те)** или **суди(те) сам(и)** — уйлап кара(гыз). **Судя по** — ...-га карагапда. **Судить (да** или **и) рядить** *разг.* — сөйләнү, сөйләнеп тору, фикер йөртү.

**СУДИ'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** судлашу; *судиться с соседом* — күрше белән судлашу; **2.** *страд.* суд ясалу, хөкем ителү.

**СУДИЯ'** *м. книж. ритор. устар.* — к. судья.

**СУ'ДНО** I *ср.* (*мн.* су́дна) — **1.** *обл.* савыт; **2.** судно, тәрәт савыты.

**СУ'ДНО** II, **СУДНО'** *ср.* (*мн.* суда́) — судно (пароход, корабль һ. б.).

**СУ'ДНЫЙ** *устар.* — суд ...-ы; *судная грамота* — суд грамотасы. ◇ **Судный день** *религ.* — ахыр заман, кыямәт көне, мәхшәр көне.

**СУДОВЕ'РФЬ** *ж.* — судоверфь, суднолар төзү верьфе.

**СУДОВЛАДЕ'ЛЕЦ** *м.* — судно хуҗасы.

**СУДОВОДИ'ТЕЛЬ** *м.* — суднолар йөртүче.

**СУДОВОЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мор.* — суднолар йөртү.

**СУДОВО'Й** — **1.** судно ...-ы, суднолар ...-ы; *судовое устройство* — судно төзелеше; *судовой механизм* — судно механизмы; **2.** судно ...-ы, суднода эшләүче; *судовой механик* — судно механигы.

**СУДОВЩИ'К** *м. простореч. устар.* — к. судовладелец.

**СУДОГОВОРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *право* — судта сөйләү (судлашучы якларның сөйләве).

**СУДО'К** *м.* — **1.** савыт (каймак, соус, подливка кебек нәрсәләр салып куя торган савыт); **2.** судок (борыч, серкә, горчица савытларын бергә утыртып йөртә торган оя); **3.** *только мн.* судки (кайнар аш салып берсе өстенә берсен куеп йөртә торган мискиләр).

**СУДОМО'ЙКА** *ж.* — **1.** савыт-саба юучы, кашык-аяк юучы (хатын-кыз); **2.** савыт-саба (кашык-аяк) юа торган бина; **3.** кашык-аяк мунчаласы (савыт-саба, кашык-аяк юа торган мунчала).

**СУДОПОДЪЁМ** *м. мн.* нет, *тех.* — баткан судноларны күтәрү.

**СУДОПОДЪЁМНИК** *м. тех.* — судно күтәргеч (мәсәлән, төрле биеклектәге сулыкларны бер-берсенә куша торган каналларда судноларны күтәрү өчен хезмәт итә торган бассейнлы җайланма).

**СУДОПОДЪЁМНЫЙ** *тех.* — судно(лар) күтәрү ...-ы; *судоподъёмные работы* — судолар күтәрү эшләре.

**СУДОПРОИЗВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *право* — суд процессы (куелган тәртип буенча суд эшләрен алып бару).

**СУДОРАБО'ЧИЙ** *м. спец.* — судно эшчесе (судноларда йөк төяү, бушату һ. б. эшләрне башкаручы эшче).

**СУДОРЕМО'НТ** *м. мн.* нет, *тех.* — суднолар ремонтлау.

**СУДОРЕМО'НТНЫЙ** *тех.* — суднолар ремонтлау ...-ы; *судоремонтные работы* — судно(лар) ремонтлау эшләре.

**СУ'ДОРОГА** *ж.* — көзән җыеру, тартышу.

**СУ'ДОРОЖНЫЙ** — **1.** калтыранып..., калтыранулы, көзән җыергандагы кебек; *судорожные движения* — калтыранулы хәрәкәтләр; **2.** *перен.* өзәләнеп ..., тынгысыз; *судорожная деятельность* — өзәләнеп эшләү; **3.** буылып-буылып; *судорожная кашель* — буылып-буылып ютәлләү. ◇ **Судорожный плач** — сулкылдап елау.

**СУДОСТРОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — суднолар төзү.

**СУДОСТРОИ'ТЕЛЬ** *м.* — суднолар төзүче.

**СУДОСТРОИ'ТЕЛЬНЫЙ** — суднолар төзү ...-ы; *судостроительный завод* — суднолар төзү заводы.

**СУДОУСТРО'ЙСТВО** *ср. мн.* нет, *право* — суд төзелеше, суд корылышы (суд органнары системасы һәм суд эшләрен алып бару тәртибе).

**СУДОХО'Д, СУДОХО'ДЕЦ** *м. обл.* — суднолар йөртүче.

**СУДОХО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет — суднолар йөри алырлык булу, суднолар йөрерлек булу.

**СУДОХО'ДНЫЙ** — суднолар йөри ала торган, суднолар йөри алырлык ....

**СУДОХО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — суднолар йөреше.

**СУДЬБА'** *ж.* — язмыш, тәкъдир, күрәчәк. ◇ **Какими судьбами?** *разг.* — нинди язмыш ташлады сине (сезне) монда? Нинди җилләр ташлады? **Оставить (бросить) на произвол судьбы** — к. произвол. **Не судьба** *с инф.* — язмаган; *не судьба ему жить здесь* — аңа монда торырга язмаган.

**СУДЬБИ'НА** *ж. мн.* нет, *нар.-поэт.* — к. судьба.

**СУДЬЯ'** *м.*—1. судья, хаким, бәя бирүче; *он в этом деле плохой судья* — ул бу эштә начар судья; 2. судья, хаким; *народный судья* — халык судьясы; 3. *спорт.* судья.

**СУЕВЕ'Р** *м. разг.*— хорафатчы, хорафатка ышанучы.

**СУЕВЕ'РИЕ** *ср.* — хорафат; хорафатка ышану.

**СУЕВЕ'РИТЬ** *несов. разг. устар.*— хорафатка ышану.

**СУЕВЕ'РКА** *ж. разг.*— к. суевер.

**СУЕВЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — хорафатларга ышанучанлык, хорафатларга ышану.

**СУЕВЕ'РНЫЙ** —1. хорафатларга ышанучы ...; *суеверный человек* — хорафатларга ышанучы кеше; 2. хорафатлы, хорафатка нигезләнгән; *суеверные обряды* — хорафатка нигезләнгән йолалар.

**СУЕВЕ'РСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.* — к. суеверие.

**СУЕВЕ'РСТВОВАТЬ** *несов. разг. устар.*— к. суеверить.

**СУЕМУ'ДРИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— акыл сату, бушка акыл сату.

**СУЕСЛО'ВИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— буш сүзлелек.

**СУЕТА'** *ж.*—1. фани дөнья, фани нәрсә; 2. *только ед.* мәшәкать, ыгы-зыгы, әрлебирле чабу; 3. *только. ед. разг.* ыгы-зыгы килүчән кеше. ◇ **Суета сует** *церк., книж. устар.*— фани дөнья мәшәкате.

**СУЕТИ'ТЬСЯ** *несов.* — ыгы-зыгы килү, мәшәкатьләнү, әрле-бирле чабу.

**СУЕТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет—1. ыгы-зыгы килү(чәнлек); 2. тынгысызлык, борчулы булу; мәшәкатьлелек.

**СУЕТЛИ'ВЫЙ** — 1. ыгы-зыгы килүчән, бушка ашыгучан; *суетливый человек* — ыгы-зыгы килүчән кеше; 2. *разг.* тынгысыз, борчулы, мәшәкатьле; *суетливая работа*— борчулы эш.

**СУ'ЕТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.*— к. суета 1.

**СУ'ЕТНЫЙ** *книж.*—1. *устар.* фани, буш; *суетные надежды* — буш өметләр; 2. *устар.* ялган шөһрәт сөючән; мәгънәсез, буш; *суетный человек* — буш кеше; 3. ыгы-зыгылы; мәшәкатьле; тынгысыз, борчулы; *суетная жизнь* — мәшәкатьле тормыш.

**СУЕТНЯ'** *ж. мн.* нет, *разг.*— к. суета 2.

**СУЖДЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. книж. устар.* (*действие*) к. судить 1; 2. фикер, уй; *высказать свое суждение* — үз фикерени әйтү (әйтеп бирү, сөйләп бирү); 3. хөкем (логикада).

**СУЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. сузить, сузиться.

**СУ'ЖЕНАЯ** *ж. в знач. сущ.*— к. невеста.

**СУ'ЖЕНЫЙ** —1. *обл.* язган, алдан билгеләнгән; 2. *в знач. сущ.* к. жених.

**СУЖЕРЁБАЯ** — буаз (бия, ишәк турында).

**СУ'ЖИВАТЬ** *несов.*— к. сузить.

**СУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. сузиться; 2. *страд.* тарайтылу, бераз тарайтылу.

**СУ'ЗИТЬ** *сов.*— тарайту, тарайта төшү, бераз тарайту.

**СУ'ЗИТЬСЯ** *сов.*— тараю, тарая төшү, бераз тараю.

**СУК** *м.*— ботак. ◇ **В сук попасть** — нәкъ өстенә басу, туры китерү, өстенә сугу.

**СУ'КА** *ж.*— ана эт, кәнтәй, әнчек.

**СУ'КИН: сукин сын** (сукина дочь, сукины дети) *простореч. бран.*— эттән туган (орышу сүзе).

**СУКНО'** *ср.*— постау, сукно. ◇ **Под сукно положить** (дело, просьбу) *перен.*— сукно астына салу (эшне, үтенечне тикшермәү, бернинди дә карар чыгармау). **Под сукном лежать** (о деле, просьбе) *перен.*— сукно астында яту (тикшерелмәү, бернинди дә карар чыгарылмау, ходка җибәрелмәү).

**СУКНОВА'Л** *м. спец.*— постау басучы, сукно басучы.

**СУКНОВА'ЛКА** *ж. спец.*— постау басу машинасы, сукно басу машинасы.

**СУКНОВА'ЛЬНЫЙ** *спец.*—1. постау (сукно) басу ...-ы, постау (сукно) баса торган; *сукновальная машина* — постау (сукно) басу машинасы; 2. постау (сукно) басканда кулланыла торган; *сукновальная глина* — постау (сукно) басканда кулланыла торган балчык; 3. постау (сукно) басучы ...; *сукновальный мастер* — постау (сукно) басучы мастер.

**СУКНОВА'ЛЬНЯ** *ж. спец.* — постау (сукно) басу мастерское.

**СУКНОВА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — к. сукновал.

**СУКНОМО'ЙКА** *ж. тех.*— сукно югыч аппарат (кәгазь ясау машиналарының сукносын юа торган аппарат).

**СУКОВА'ТЫЙ** — ботаклы, күп ботаклы.

**СУКО'НКА** *ж.*— сукно кисәге, постау кисәге.

**СУКО'ННЫЙ** — 1. постау ..., сукно ...; постаудан (сукнодан) тегелгән; *суконные брюки* — сукно чалбар; 2. постау ...-ы, сукно ...-ы; *суконная фабрика* — постау фабрикасы; 3. постау ...-ы, сукно ...-ы, постау сата торган, сукно сата торган; *суконный ряд* — постау сата торган рәт (кибетләр); 4. постау эшләп чыгаручы..., сукно эшләп чыгаручы...; *суконный мастер* — постау эшләп чыгаручы мастер. ◇ **Суконный язык** — тупас тел. **Суконное рыло** — сәүдәгәр.

**СУКО'НЩИК** *м.*—1. постаучы, сукночы (сукно эшләп чыгаручы); 2. *устар.* постау сәүдәгәре, постау (сукно) белән сәүдә итүче.

**СУ'КРОВИЦА** *ж.*—1. сүл; 2. канлы эрен.

**СУ'КРОВИЧНЫЙ** — канлы эрен ...-ы; сүл ...-ы; *сукровичные пятна* — канлы эрен таплары.

**СУЛЕМА'** *ж. мн.* нет — сүләмә (агулы матдә).

**СУЛЕМО'ВЫЙ** — сүләмә ...-ы; *сулемовый раствор* — сүләмә эремәсе.

**СУЛЁНЫЙ** *обл.*— ышандырылган, ышандырган, вәгъдә итеелгән.

**СУЛЕЯ'** *ж. обл., устар.*— яссы шешә.

**СУЛИ'ТЬ** *несов. устар., простореч.* — вәгъдә итү, ышандыру, өметләндерү.

**СУЛИ'ТЬСЯ** *несов. устар. простореч.* —

1. к. сулить; 2. *страд.* вәгъдә ителү, ышандырылу.

**СУЛТА'Н** *м.* — солтан (1. кайбер көнчыгыш илләрендә патша титулы; 2. баш киемәнә кадап куела торган каурыйлар яки кыл чук).

**СУЛТАНА'Т** *м. полит.* —1. *только ед.* солтан власте; 2. солтанат (башында солтан утырган монархистик дәүләт).

**СУЛТА'НСКИЙ** — солтан ...-ы, солтан власте ...-ы; солтанлык ...-ы; *султанский режим в старой Турции* — иске Төркиядә солтан власте режимы.

**СУЛТА'НСТВО** *ср. полит.* — к. султанат.

**СУЛТА'НЧИК** *м.* — бүрек (мәсәлән, тавык башындагы кабарып торган йоннар).

**СУЛТА'НША** *ж. разг.* — солтан хатыны.

**СУЛЬФА'Т** *м. хим.* — сульфат (күкерт кислотасының тозлары).

**СУЛЬФИ'Д** *м.* — сульфид (күкертнең металл белән кушылмасы).

**СУЛЬФИ'Т** *м.* — сульфит (күкертле кислотаның тозлары).

**СУМА'** *ж.* —1. к. сумка 1; 2. *только ед.* хәерчелек. ◇ **Ходить с сумой** — хәер эстәп йөрү, соранып йөрү. **Пустить с сумой** — хәерчелеккә төшерү, бөлдерү. **Сума перемётная** — к. перемётный.

**СУМАСБРО'Д** *м.* — дуамал баш, дуамал кеше.

**СУМАСБРО'ДИТЬ** *несов.* — к. сумасбродничать.

**СУМАСБРО'ДКА** *ж.* — к. сумасброд.

**СУМАСБРО'ДНИЧАТЬ** *несов.* — дуамаллану, акылдан шашу.

**СУМАСБРО'ДНЫЙ** — дуамал.

**СУМАСБРО'ДСТВО** *ср.* — дуамаллык.

**СУМАСБРО'ДСТВОВАТЬ** *несов.* — к. сумасбродничать.

**СУМАСШЕ'ДШИЙ** — 1. акылдан язган, акылдан шашкан, тиле, дивана; *сумасшедший человек* — акылдан язган кеше; 2. акылсызлар ...-ы, тиләләр ...-ы; *сумасшедший дом* — акылсызлар йорты; 3. *перен. разг.* чиктән тыш зур, акылга сыймаслык; *сумасшедший успех* — чиктән тыш зур уңыш.

**СУМАСШЕ'СТВИЕ** *ср. мн.* нет —акылдан шашу, акылдан язганлык, акылдан язу.

**СУМАСШЕ'СТВОВАТЬ** *несов.* — акылсыз эш итү, алдын-артын уйламыйча эш итү.

**СУМАТО'ХА** *ж. мн.* нет — ыгы-зыгы, шау-шу, ашыгычлык.

**СУМАТО'ШИТЬСЯ** *несов. разг.* — ыгызыгы килү, шау-шу килү, ашык-пошык эшләү (йөрү).

**СУМАТО'ШЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — ыгы-зыгы килү(чәнлек), ашык-пошык эшләү(чәнлек).

**СУМАТО'ШЛИВЫЙ** *разг.* — ыгы-зыгы килүчән, ашык-пошык эшләүчән (йөрүчән).

**СУМАТО'ШНЫЙ** *разг.* — к. суматошливый.

**СУМБУ'Р** *м. мн.* нет — буталчыклык, чуалчыклык.

**СУМБУ'РИТЬ** *несов. разг. фам.* — 1. буталчыклык (чуалчыклык) кертү; буталчыклык тудыру; 2. мәгънәсез нәрсәләр сөйләү.

**СУМБУ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — буталчыклык, мәгънәсезлек.

**СУМБУ'РНЫЙ** — буталчык, чуалчык, буталчыклы, чуалчыклы.

**СУМБУ'РЩИНА** *ж. мн.* нет, *разг. фам. пренебр.* — к. сумбурность.

**СУ'МЕРЕЧНИК** *м.* —1. *разг.* эңгер-меңгер чакны яратучы (кеше), эңгер-меңгер чакта сөйләшеп утырырга яратучы; 2. *зоол.* эңгер-меңгер чакта йөрергә чыга торган хайван.

**СУ'МЕРЕЧНИЦА** *ж.* — 1. *разг. шутл.* к. сумеречник 1; 2. эңгер-меңгер күбәләге.

**СУ'МЕРЕЧНЫЙ** —1. эңгер-меңгер, караңгылы-яктылы; күз бәйләнгән; *сумеречное время* — эңгер-меңгер вакыт; 2. *зоол.* эңгер-меңгер чакта йөрергә чыга торган (хайван турында); 3. *перен. книж.* төшенке; *сумеречное настроение* — төшенке настроение. ◇ **Сумеречная пора капитализма** — капитализмның бетүгә йөз тоткан чагы. **Сумеречное состояние** *мед.* — аңлы-миңле хәл (кайбер психик авырулар белән авырганда).

**СУ'МЕРКИ** *ед.* нет —1. эңгер-меңгер вакыт (чак), караңгылы-яктылы вакыт, күз бәйләнгән чак; 2. *перен.* кояшы баю, гомере бетү, сүнү; *сумерки капитализма* — капитализмның гомере бетү.

**СУ'МЕРНИЧАТЬ** *несов. разг.* — эңгер-меңгер чакта сөйләшеп утыру, караңгы төшкәнне көтеп утыру, караңгы төшкәнне көтеп сөйләшеп утыру.

**СУМЁТ** *м. обл.* — к. сугроб.

**СУМЕ'ТЬ** *сов. с инф.* — булдыра алу, ...-а алу; *не сумею сделать* — эшли алмам.

**СУ'МИНА** *ж. обл.* — бер як букча (хайван сыртына ике якка салынмалы букчаның берсе).

**СУ'МКА** *ж.* — сумка, букча. ◇ **Пастушья сумка** *бот.* — көтүче сумкасы (чүп үлән).

**СУ'ММА** *ж.* — 1. *мат.* сумма; 2. *книж.* җыенысы, барлыгы, барысы; *вся сумма человеческих знаний* — кешелек белемнәренең барлыгы; 3. сума; *большая сумма* — зур сума. ◇ **В сумме** (взятое, взятые) *книж.* — барысын бергә (алганда).

**СУММА'РНЫЙ** *книж.* — 1. суммасы хисаплап чыгарылган, суммасы чыгарылган; *суммарные показатели* — суммасы хисаплап чыгарылган күрсәткечләр; 2. *перен.* гомуми, гомумиләштерелгән, нәтиҗәдә килеп чыккан; *суммарные впечатления* — гомуми тәэсирләр.

**СУММИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* —1. суммасын китереп чыгару, суммасын хисаплап чыгару, суммасын чыгару; *суммировать показатели* — күрсәткечләрнең суммасын хисаплап чыгару; 2. *перен.* гомумиләштерү, гомум нәтиҗә чыгару, гомумиләштереп нәтиҗә чыгару; *суммировать опыт* — (алынган) тәҗрибәне гомумиләштереп нәтиҗә чыгару.

**СУММИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. суммасы хисаплап чыгарылу, суммасы чыгарылу; 2. *перен.* гомумиләштерелү, гомум нәтиҗә чыгарылу, гомумиләштереп нәтиҗә чыгарылу.

**СУММОВО'Й** *спец.* — күпме акча кирәк булганын күрсәтеп...; *представить план*

*работ в суммовом выражении* — эшләр өчен күпме акча кирәк булганын күрсәтеп тәзергә.

**СУ'МНИЧАТЬ** *сов. разг.* — к. умничать.

**СУ'МНО** *нареч.* — уйланып; *сумно сидеть* — уйланып утыру.

**СУ'МНЫЙ** *обл.* — күңелсез, төшенке, уйчан; *сумное настроение* — төшенке настроение.

**СУМНЯ'СЯ** и **СУМНЯ'ШЕСЯ**; **ничтоже сумняся** или **сумняшеся** — һич тә шикләнмичә, һич тә икеләнмичә.

**СУ'МОЧКА** *ж.* — **1.** к. сумка; **2.** к. ридикюль.

**СУ'МОЧНЫЙ** — сумка(лар)...-ы, букча(лар)...-ы; *сумочное производство* — сумкалар производствосы.

**СУ'МРАК** *м. мн.* нет — ярым караңгылык.

**СУ'МРАЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет —**1.** ярым караңгылык; **2.** *перен.* кәефсезлек, күңелсезлек, боеклык, караңгы чырайлылык.

**СУ'МРАЧНЫЙ** — **1.** ярым караңгы; караңгылы-яктылы; *сумрачный лес* — ярым караңгы урман; **2.** *перен.* кәефсез, күңелсез, боек, караңгы чырайлы; *сумрачный человек* — боек кеше.

**СУМЧА'ТКА** *ж. зоол.* — сумкалы хайван, букчалы хайван (мәсәлән, кенгуру).

**СУ'МЧАТЫЙ** *зоол. бот.* — сумкалы, букчалы; *сумчатые животные* — букчалы хайваннар.

**СУМЯ'ТИЦА** *ж. мн.* нет — к. суматоха.

**СУНДУ'К** *м.* — сандык.

**СУНДУ'ЧНИК** *м.* — сандыкчы, сандыклар ясаучы (мастер).

**СУНДУ'ЧНЫЙ** — сандык ...-ы; *сундучная крышка* — сандык капкачы.

**СУ'ННА** *ж. рел.* — сөннәт (коръәнгә өстәмәләр һәм аңлатмалар белән бергә Мөхәммәт пигамбәр турында риваятьләр).

**СУННИ'Т** *м. рел.* — сөнни (ислам динендә сөннилар мәзһәбендәге кеше).

**СУ'НУТЬ** *сов.* — к. совать.

**СУ'НУТЬСЯ** *сов. разг.* — к. соваться 1, 2. ◇ **Куда ни сунься** *разг.* — кая гына тыгылма; бөтен җирдә; һәр җирдә.

**СУП** *м.* — аш, шулпа; *(с крупой)* өйрә.

**СУПЕРАРБИ'ТР** *м. спец.* — суперарбитр (соңгы карарны чыгаручы югары арбитр).

**СУПЕРОБЛО'ЖКА** *ж. тип.* — суперобложка (китапның тышы өстенә куела торган кәгазь тыш).

**СУПЕРФОСФА'Т** *м. спец.* — суперфосфат (ашламаның бер төре)

**СУ'ПЕСКОВЫЙ** — к. супесчаный.

**СУ'ПЕСНЫЙ** — к. супесчаный.

**СУ'ПЕСОК** *м.* — комлы туфрак.

**СУПЕСЧА'НЫЙ** — комлы; *супесчаные почвы* — комлы туфраклар.

**СУ'ПЕСЬ** *ж.* — к. супесок.

**СУ'ПИТЬ** *несов. разг.* — к. насупить.

**СУ'ПИТЬСЯ** *несов. разг.* — к. насупиться.

**СУ'ПНИК** *м.*, **СУ'ПНИЦА** *ж. спец. обл.* — (шулпа сала торган) миски.

**СУПОВО'Й** — аш ...-ы, шулпа ...-ы; шулпа сала торган; *суповая миска* — аш мискисе.

**СУПО'НИТЬ** *несов.* — чөелдерекне тартып бәйләү.

**СУПО'НИТЬСЯ** *несов. страд.* — чөелдерекне тартып бәйләнү.

**СУПО'НЬ** *ж.* — чөелдерек.

**СУПОРО'САЯ** — буаз (дуңгыз турында).

**СУПОРО'СНОСТЬ, СУПОРО'СОСТЬ** *ж. мн.* нет — буазлык (дуңгыз турында).

**СУПОСТА'Т** *м. нар.-поэт. ритор.* — дошман; явыз (кеше).

**СУПРОТИ'В** *нареч.* и *предлог с. род. п. простореч.* — к. против 1, 2, 4.

**СУПРОТИ'ВНИК** *м. простореч.* — дошман.

**СУПРОТИ'ВНИЧАТЬ** *несов. простореч.* — каршылык күрсәтү, киреләнү.

**СУПРОТИ'ВНЫЙ** — **1.** *спец.* каршыдаш, кара-каршы; *супротивные листья* — кара-каршы яфраклар; **2.** *простореч.* каршы; *супротивный ветер* — каршы җил.

**СУПРУ'Г** *м. книж. устар* — ир; *мой супруг* — минем ирем.

**СУПРУ'ГА** *ж. книж. устар.* — хатын; *моя супруга* — минем хатыным.

**СУПРУ'ГИ** *мн. книж.* — ир белән хатын.

**СУПРУ'ЖЕСКИЙ** *книж.* — ирле-хатынлы, ир белән хатын ...-ы; *супружеская жизнь* — ир белән хатын тормышы.

**СУПРУ'ЖЕСТВО** *ср. книж. устар.* — ирле-хатынлылык; ирле-хатынлы яшәү, ир белән хатын булып яшәү.

**СУПРУ'ЖНИЦА** *ж. простореч.* — к. супруга.

**СУПРЯ'ГА** *ж. с.-х.* —**1.** *обл.* парга җигелгән эш хайваннары (җир эшкәртү өчен төрле хуҗаның парга җигелгән эш хайваннары); **2.** *только ед.* бергә кушылып җир эшкәртү (төрле хуҗаның эш хайваннарын парга җигеп, җир эшкәртү).

**СУ'ПРЯДКИ** *мн. обл.* — җеп эрләү өмәсе (утырмага килгән кызларның җеп эрләү өмәсе).

**СУПРЯ'ЖНИК** *м., с.-х. обл.* — бергә кушылып җир эшкәртүче.

**СУРГУ'Ч** *м.* — сургыч.

**СУРГУ'ЧНЫЙ** — сургыч..., сургычтан ясалган; *сургучная печать на конверте* — конвертта сургыч печать.

**СУРДИ'НА, СУРДИ'НКА** *ж. муз.* — алаша (скрипка тавышын йомшарту өчен, аның кыллары астына кыстырып куела торган тараксыман җайланма). ◇ **Под сурдинку** (что-н. сделать, сказать) *перен. разг.* — яшерен генә, әкрен генә (эшләү, әйтү), пышылдап кына (әйтү).

**СУРДОПЕДАГО'Г** *м. спец.* — сурдопедагог, чукрак-телсезләрне укытучы.

**СУРДОПЕДАГО'ГИКА** *ж. мн.* нет — сурдопедагогика, чукрак-телсезләрне укыту методикасы.

**СУРЕ'НЩИК** *м. старин.* — сорнайда уйнаучы.

**СУРЕ'ПИЦА, СУРЕ'ПКА** *ж. бот., с.-х.* — **1.** шепкән; **2.** эт какысы (чүп үлән).

**СУРЕ'ПНЫЙ** *бот., с.-х.* — шепкән ...-ы;

эт какысы ...-ы; *сурепное масло* — шепкән мае.

**СУ'РЖА, СУ'РЖАНКА** *ж.*, **СУ'РЖИК** *м. с.-х., бот.* — **1.** катнаш чәчелгән арыш белән бодай; **2.** суржа (арыш белән бодай катнашуы нәтиҗәсендә килеп чыккан бодай сорты).

**СУ'РИК** *м. мн.* нет, *спец.* — сурик (кызыл яки кызгылт-көрән төстәге буяу).

**СУ'РИКОВЫЙ** — кызыл, кызгылт-көрән; *суриковый цвет* — кызгылт-көрән төс.

**СУРКО'ВЫЙ** — байбак ...-ы; *сурковая норка* — байбак өне.

**СУРНА'** *ж. старин.* — к. зурна.

**СУРО'ВЕТЬ** *несов.* — катылана бару, кырыслана бару; кискенләшә бару, салкынлана бару.

**СУРО'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** катылык, салкынлык; **2.** *перен.* катылык, кырыслык; **3.** *перен.* авырлык, ачылык.

**СУРО'ВСКИЙ, СУРОВСКО'Й** *устар.* — тукымалар ...-ы; тукымалар сату ...-ы; *суровский магазин* — тукымалар магазины.

**СУРО'ВЫЙ** — **1.** агартылмаган; *суровая ткань* — агартылмаган тукыма; **2.** ачы салкын, каты салкын; *суровая зима* — бик салкын кыш; **3.** *перен.* кырыс; каты; *суровый человек* — кырыс кеше; *суровое обращение* — каты мөгамәлә; **4.** *перен.* авыр, ачы; *суровая правда* — ачы хакыйкать. ◇ **Суровые нитки** — тегәрҗеп.

**СУРОВЬЁ** *ср. мн.* нет — агартылмаган тукыма.

**СУРО'К** *м.* — байбак (хайван).

**СУРРОГА'Т** *м.* — 1. суррогат (үзенең кайбер сыйфатлары белән генә икенче бер нәрсәне алмаштыра ала торган нәрсә); *сахарин — суррогат сахара* — сахарин шикәрнең суррогаты; **2.** суррогат, ясалма әйбер (продукт).

**СУРРОГА'ТНЫЙ** *книж.* — суррогат ...; *суррогатный продукт* — суррогат продукт.

**СУРЬЁЗНЫЙ** *устар.* — к. серьёзный.

**СУРЬМА'** *ж. мн.* нет — сөрмә (1. химик элемент; 2. чәч, каш, мыек каралту өчен кулланыла торган буяу).

**СУРЬМИ'ЛО** *ср. устар.* — к. сурьма 2.

**СУРМИ'ТЬ** *несов. устар.* — сөрмәләү, сөрмә тарту.

**СУРМИ'ТЬСЯ** *несов. устар.* — **1.** сөрмә тарту; **2.** *страд.* сөрмә тартылу.

**СУРЬМЯНИ'СТЫЙ** *хим., мин.* — сөрмәле; *сурьмянистое серебро* — сөрмәле көмеш.

**СУРЬМЯНО'Й, СУРЬМЯ'НЫЙ** *хим. мин.* — сөрмә ...-ы; *сурьмяной блеск* — сөрмә ялтыравыгы.

**СУСА'К** *м. бот. обл.* — сусак, кырлы куга.

**СУСА'ЛА** *мн. обл., простореч. вульг.* — бит, янак; *ударить по сусалам* — яңакларына берне бирү.

**СУСА'ЛИТЬ** *несов. устар.* — алтын (көмеш, бакыр яки кургашын) кәгазь белән каплау (бизәкләү).

**СУСА'ЛИТЬСЯ** *несов. страд. устар.* — алтын (көмеш, бакыр, яки кургашын) кәгазь белән каплану (бизәкләнү).

**СУСА'ЛЬ** *ж. мн.* нет, *устар.* — алтын (көмеш, бакыр яки кургашын) кәгазь.

**СУСА'ЛЬНЫЙ** *перен. разг.* — артык төче, сентименталь. ◇ **Сусальное золото** — алтын кәгазь. **Сусальное серебро** — көмеш кәгазь. **Сусальный пряник** — алтын (көмеш) кәгазьгә төрелгән прәннек.

**СУСЕ'К** *м. обл.* — к. закром.

**СУ'СЛИК** *м.* — йомран (кимерүче җәнлек).

**СУ'СЛИТЬ** *несов.* — 1. чөмерү, акрынлап суырып эчү; *суслить квас* — квас чөмерү; **2.** *простореч.* селәгәйләү, төкерекләү; майга катыру; *суслить пальцы* — бармакларны төкерекләү; **3.** *обл.* сослалау, сосла салу; *суслить кашу* — боткага сосла салу.

**СУ'СЛИТЬСЯ** *несов.* — 1. *обл.* чөмерү, акрын гына эчү; акрын гына ашау; *долго суслился с чаем* — чәй чөмереп бик озак утырды; **2.** *простореч.* селәгәйләнү, төкерекләнү; майга катырылу.

**СУ'СЛИЧИЙ** — йомран ...-ы; *сусличья нора* — йомран оясы.

**СУ'СЛО** *ср. мн.* нет — сосла.

**СУСЛО'Н** *м. обл.* — сослан.

**СУСО'ЛИТЬ** *несов. простореч.* — **1.** к. суслить 2; **2.** *обл.* йомарлау; *сусолить тряпку в руках* — кулда чүпрәк йомарлау.

**СУСО'ЛИТЬСЯ** *несов. обл.* — к. суслиться 1, 2.

**СУСТА'В** *м.* — буын.

**СУСТАВНО'Й** — буын ...-ы; буыннарда була торган; *суставной ревматизм* — буын ревматизмы.

**СУСТА'ВЧАТЫЙ** *спец.* — буынлы, буынбуын ...; буыннардан торган.

**СУТА'НА** *ж.* — сутана (католик руханиларының озын итеп тегелгән өс киемнәре).

**СУТЕНЁР** *м.* — сутенёр, фахишә сәөркәсе, ата мәче (капиталистик җәмгыятьтә: фахишә акчасына яшәүче ир кеше).

**СУ'ТКИ** *только мн.* — тәүлек.

**СУ'ТОЛОКА** *ж. мн.* нет — ыгы-зыгы; шау-шу, этеш-төртеш.

**СУ'ТОЛОЧИТЬСЯ** *несов. простореч.* — буталып йөрү, эшсез ыгы-зыгы куптарып йөрү.

**СУ'ТОЛОЧНЫЙ** *простореч.* — **1.** ыгызыгылы, кеше күп булган, халык күп булган; 2. к. суматошливый.

**СУ'ТОЧНЫЙ** — 1. (бер) тәүлек эчендә булган, (бер) тәүлек буена булган; *суточные изменения погоды* — һаваның (бер) тәүлек эчендә булган үзгәрешләре; *суточный дождь* — (бер) тәүлек (буена) яуган яңгыр; **2.** бер тәүлеклек ...; *суточный цыплёнок* — бер тәүлеклек чебеш; **3.** тәүлек исәбеннән бирелә торган; *суточные деньги* — тәүлек исәбеннән түләнә торган акча; **4.** *только мн. в знач. сущ.* суточный акча; *выдача суточных командированным* — командировкага җибәрелә торганнарга суточный акчаларны бирү.

**СУТУ'ГА** *ж. обл.* — тимер чыбык.

**СУТУ'ЛИНА** *ж. разг.* — аз гына бөкрелек.

**СУТУ'ЛИТЬ** *несов.* — аз гына бөкрәйтү.

**СУТУ'ЛИТЬСЯ** *несов.* — аз гына бөкрәю.

**СУТУЛОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. сутулость.

**СУТУЛОВА'ТЫЙ** — к. сутулый.

**СУТУ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — аз гына бөкрелек, бөкрәеп йөрү.

**СУТУ'ЛЫЙ** — аз гына бөкре, аз гына бөкресе чыккан, калку җилкәле.

**СУТЬ** I *ж. мн.* нет — асылы, төп нигезе, төп җирлеге; *суть дела* — эшнең асылы. ◇ **По сути дела** — чынында, асылда.

**СУТЬ** II *книж. устар.* — „быть" фигыленең күплектә кулланыла торган 3 зат хәзерге заман формасы; татар телендә гадәттә „алар" сүзе белән тәрҗемә ителеп, җөмлә ахырына куела; *львы, тигры и пантеры суть хищные животные* — арсланнар, юлбарыслар һәм чуар юлбарыслар — ерткыч хайваннар алар.

**СУТЯ'ГА** *м.* и *ж. простореч.* — к. сутяжник.

**СУТЯ'ЖИТЬ** *несов. разг. устар.* — к. сутяжничать.

**СУТЯ'ЖНИК** *м.*, **СУТЯ'ЖНИЦА** *ж.* —судлашырга яратучы, дәгъвалашырга яратучы.

**СУТЯ'ЖНИЧАТЬ** *несов. разг.* — судлашу, судлашып йөрү, дәгъвалашып йөрү (төрле хәйләле, хәтта начар юллар белән үзенә файда чыгаруны күз алдында тотып судлашып йөрү).

**СУТЯ'ЖНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.* — судлашырга ярату, дәгъвалашырга ярату, дәгъвачыллык.

**СУТЯ'ЖНЫЙ** *разг.* — 1. дәгъвалашырга яратучы, судлашырга яратучы; дәгъвачыл; *сутяжный человек* — дәгъвалашырга яратучы кеше; 2. дәгъвалы; *сутяжное дело* — дәгъвалы эш.

**СУФЛЕ'** *ср. нескл.* — суфле (пирожныйның бер төре).

**СУФЛЁР** *м. театр.* — суфлёр (сәхнәдә уйнаучыларга рольдәге сүзләрне әйтеп торучы).

**СУФЛЁРСКИЙ** — суфлёр ...-ы; суфлёрлык ...-ы; *суфлёрская будка* — суфлёр будкасы.

**СУФЛИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. суфлёр булу, суфлёр булып эшләү, сәхнәдә уйнаучыларга әйтеп тору; 2. *перен. разг. ирон. шутл.* әйтеп тору, өйрәтеп тору.

**СУФРАЖИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — суфражизм (XX йөзнең башында Англиядә хатын-кызларга ирләр белән тигез сайлау хокукы бирүне таләп итүче буржуаз хәрәкәт).

**СУФРАЖИ'СТКА** *ж.* — суфражистка, суфражизм тарафдары.

**СУФРАЖИ'СТСКИЙ** *полит.* — суфражизм ...-ы; суфражистлар ...-ы; *суфражистское движение* — суфражистлар хәрәкәте.

**СУ'ФФИКС** *м. лингв.* — суффикс, сүз ясаучы кушымча.

**СУФФИКСА'ЛЬНЫЙ** *лингв.* — суффиксаль, суффикс булган, кушымча булган; *суффиксальная часть слова* — сүзнең кушымча булган өлеше.

**СУФФИКСА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *лингв.* — 1. суффикс ярдәмендә сүзләр ясау, кушымча ярдәмендә сүзләр ясау; 2. сүзнең составында суффикс (кушымча) булу.

**СУХА'РНИК** *м.* — 1. сохари киптерүче, сохари киптереп ясаучы; 2. *разг. фам. шутл.* сохари ашарга яратучы.

**СУХА'РНИЦА** *ж.* — 1. к. сухарник 1; 2. сохари савыты, сохари сала торган ваза (тәлинкә).

**СУХА'РНЫЙ** — 1. сохари ...-ы; *сухарный цех завода* — заводның сохари цехы; 2. сохарилы, сохаридан ясалган; *сухарный квас* — сохаридан ясалган квас.

**СУХА'РНЯ** *ж.* — сохари киптерү урыны.

**СУХА'РЬ** *м.* — 1. сохари, киптергән икмәк кисәге; 2. *перен.* кипкән балык (бик ябык кеше турында әйтелә); 3. *перен.* коры кеше, каты күңелле кеше.

**СУХМЕ'ННЫЙ** *обл.* — коры, явым-чәчемсез, явым-төшемсез; *сухменный год* — коры ел.

**СУХМЕ'НЬ** *ж. мн.* нет, *обл.* — 1. коры һава, корылык; 2. кызу коры җил; 3. к. суходол.

**СУХОВЕ'Й** — кызу, коры җил.

**СУХОВЕ'ЙНЫЙ** — кызу коры җил исә торган; *суховейные районы* — кызу коры җил исә торган районнар.

**СУХОВЕ'РХИЙ** и **СУХОВЕРШИ'ННЫЙ** *обл.* — корыган башлы (агачлар турында).

**СУХОГРУ'ЗНЫЙ** *спец.* — коры әйберләр төяп ташый торган (мәсәлән, судно, баржа).

**СУХОДО'Л** *м.* — коры үзәнлек.

**СУХОДО'ЛЬНЫЙ** — коры үзәнлек ...-ы; коры үзәнлектә үсә торган; *суходольное сено* — коры үзәнлек печәне.

**СУХОЖИ'ЛИЕ** *ср.* — сеңер.

**СУХОЗА'ДЫЙ** — чандыр саллы, арт саны ябык; *сухозадая лошадь* — арт саны ябык ат.

**СУХО'Й** 1. — коры; *сухая тряпка* — коры чүпрәк; *сухой воздух* — коры һава; *сухая дорога* — коры юл; 2. кипкән, киптерелгән; *сухие фрукты* — кипкән (киптерелгән) җимешләр; 3. корыган; *сухой куст* — корыган куак; 4. *разг.* ябык, арык, чандыр; *сухой старик* — ябык карт; 5. *перен.* коры, салкын; *сухой взгляд* — салкын караш. ◇ **Сухая молния** *обл.* — аҗаган, елдырым. **В сухе да в тепле** *простореч.* — коры да һәм жылы да; коры һәм жылы җирдә. **Сухо-насухо** (вытереть) — коп-коры итеп (сөртеп алу).

**СУХОЛЮ'Б** *м. бот.* — коры җирдә үсә торган үсемлек, коры җирне ярата торган үсемлек.

**СУХОЛЮБИ'ВЫЙ** *бот.* — коры җирне ярата торган, коры җирдә үсә торган.

**СУХОМЯ'ТКА** *ж. мн.* нет, *простореч.* — коры аш, коры-сары (ашамлык).

**СУХОПА'РЫЙ** *разг.* — чандыр, ябык, арык.

**СУХОПОДСТО'Й** *м. мн.* нет, *обл.* — к. сухостой 1.

**СУХОПОДСТО'ЙНЫЙ** *обл.* — к. сухостойный 1.

**СУХОПУ'ТНЫЙ** —1. коры жир ...-ы, коры жирдәге; *сухопутный транспорт* — коры жир транспорты; 2. коры жирдә яшәүче; *сухопутные животные* — коры жирдә яшәүче хайваннар.

**СУХОПУ'ТЬЕ** *ср. мн.* нет, *разг.*— коры юл (ягъни су юлы түгел).

**СУХОРУ'КИЙ** — корыган куллы.

**СУХОСТО'Й** *м.*—1. *только ед. собир.* корыган агачлар, тамырында корыган агачлар; 2. *с.-х.* сыер ташлаткан вакыт, сыер сөт ташлаган вакыт.

**СУХОСТО'ЙНЫЙ** — 1. тамырында корыган; *сухостойный лес* — тамырында корыган урман; 2. *с.-х.* сөт ташлаган.

**СУ'ХОСТЬ** *ж. мн.* нет — корылык.

**СУХОТА'** *ж. мн.* нет —1. *разг.* к. сухость; 2. *обл. нар.-поэт.* сагыш, борчылу, мәшәкать.

**СУХОТЕ'ЛЫЙ** *простореч.*— к. сухопарый.

**СУХО'ТКА** *ж. мн.* нет, *обл.*— чиктән тыш ябыктыра торган авыру, киптерә торган авыру.

**СУХО'ХОНЬКИЙ** *простореч.*—коп-коры.

**СУХОЦВЕ'Т** *м. бот.*— шиңмәс гөл.

**СУХОЩА'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — ябыклык, арыклык, чандырлык.

**СУХОЩА'ВЫЙ** — к. сухопарый.

**СУХОЯДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *разг.*— коры аш, коры-сары.

**СУХОЯ'ДЕЦ** *м. разг. пренебр.*— коры аш ашап торучы, коры-сары белән тукланучы.

**СУЧЁНЫЙ** — бөтерелгән, катылган; *сучёная нить* — катылган җеп.

**СУ'ЧИЙ** — ана эт ...-ы, кәнтәй ...-ы; *сучье вымя (мед., обл).* — эт имчәге (култык астына чыга торган шеш).

**СУЧИ'ЛЬНЫЙ** — җеп бөтерү ...-ы; җеп кату ...-ы; *сучильный аппарат в текстильной промышленности* — текстиль промышленностенда җеп кату аппараты.

**СУЧИ'ЛЬЩИК** *м.*, **СУЧИ'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*— җеп бөтерүче, җеп катучы.

**СУЧИ'ТЬ** *несов.*—1. бөтерү, кату; *сучить нитки* — җеп кату; 2. к. ссучивать; 3. җәю; *сучить тесто* — камыр җәю; 4. йомарлау; *сучить бумажку* — кәгазь йомарлау. ◇ **Сучить ногами** — тыпырчыну.

**СУЧИ'ТЬСЯ** *несов.*—1. бөтерелү, катылу; *пряжа хорошо сучится* — җеп яхшы бөтерелә; 2. җәелү; *тесто хорошо сучится* — камыр яхшы җәелә.

**СУЧКОВА'ТЫЙ** — к. сукoватый.

**СУЧКО'ВЫЙ** *спец.* — агачлы, агач кисәкләре калган; *сучковая целлюлоза* — агачлы целлюлоза.

**СУЧКОРЕ'З** *м. тех.*— ботак кискеч (терлеккә ашату өчен агач ботакларын, яфрак кисә торган машина).

**СУЧО'К** *м.*—1. кечкенә ботак; 2. *только мн. тех.* (кәгазь массасындагы) агач кисәкләре. ◇ **Ни сучка, ни задоринки** или **без сучка, без задоринки** — к. задоринка.

**СУ'ША** *ж. мн.* нет —1. коры җир; 2. *простореч.* к. сушь 1.

**СУШЕНИ'НА** *ж. мн.* нет. *собир. разг.*— киптерелгән җимеш (гөмбә, яшелчә һ. б. ш.).

**СУШЁНЫЙ** — киптерелгән.

**СУШИ'ЛКА** *ж.*— сушилка (берәр нәрсәне киптереп хәзерләү өчен хезмәт итә торган аппарат яки бина).

**СУШИ'ЛО** *ср. спец.*— к. сушилка.

**СУШИ'ЛЬНЫЙ** — киптерү ...-ы; киптерә торган; *сушильный аппарат* — (берәр нәрсәне) киптерә торган аппарат.

**СУШИ'ЛЬНЯ** *ж.*— сушилка (берәр нәрсәне киптереп хәзерләү өчен хезмәт итә торган бина).

**СУШИ'ЛЬЩИК** *м.*, **СУШИ'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*— киптерүче (берәр нәрсәне киптереп хәзерләүче эшче).

**СУШИ'ТЬ** *несов.*—1. киптерү; *сушить сено* — печән киптерү; *сушить хлеб на сухари* — икмәкне сохарига киптерү; 2. корыту, көйдерү, яндыру; *палящее солнце сушит растительность* — кызу кояш үсемлекне корыта; 3. киптерү, ябыктыру, саргайту; *горе сушит человека* — кайгы кешене киптерә. ◇ **Сушить вёсла** *мор.*— ишкәкләрне су өстендә күтәреп тору (ишүдән туктап, ишкәкләрне судан чыгарып тору).

**СУШИ'ТЬСЯ** *несов.*—1. өс-башны киптерү, кибенү; *сушиться у костра* — костёр янында өс-башны киптерү; 2. кибү; *сено хорошо сушится на солнце* — печән кояшта яхшы кибә; 3. *страд.* киптерелү; корытылу.

**СУ'ШКА** *ж.* — 1. *только ед. (действие)* к. сушить 1, 2; 2. сушки, клиндер; *сушки с маком* — мәкле сушки; 3. *тех.* к. сиккатив; 4. *только ед. спец.* чылатып киптерелгән товар (күбесенчә житен, киндер сүсе турында); 5. *спец.* корсак асты йоны (дуңгызда).

**СУШЬ** *ж. мн.* нет —1. *разг.* эссе һәм яңгырсыз вакыт, эссе һәм коры вакыт; *летом была необычайная сушь* — җәй бик эссе һәм коры иде; 2. *разг.* коры туфрак; коры ботаклар; коры-сары (гомумән коры нәрсәләр); 3. *разг. обл.* коры җир, коры урын (ягъни саздык, баткаклык түгел); 4. *спец.* буш (балсыз) кәрәз; 5. *спец.* уалучан тимер.

**СУЩЕ'СТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — әһәмиятлелек, мөһимлек, житдилек.

**СУЩЕ'СТВЕННЫЙ** — әһәмиятле, асыл..., төп, мөһим, житди.

**СУЩЕСТВИ'ТЕЛЬНЫЙ: имя существительное** *грам.*— исем.

**СУЩЕСТВО'** *ср.*—1. *только ед.* к. сущность; 2. зат, кеше; җан иясе; *это было длиннолицее, длиннозубое существо* (Тургенев) — ул озынча йөзле, озын тешле бер зат иде. ◇ **Живое существо** — тереклек иясе, җан иясе. **По существу** (говорить)— төп мәсьәлә буенча (сөйләү). **По существу** или **по существу говоря** *ввод. слово* — асылда, нигездә, чынында.

**СУЩЕСТВОВА'НИЕ** *ср.*—1. яшәү, яшәеш; тормыш; 2. бар булу, барлык, булу; *я не знал о существовании этой книги* — бу китапның барлыгы турында мин белми идем;

**3.** *книж. редко* к. существо 2. ◇ **Покончить (земное) существование** *книж.* — үлү, дөньядан китү. **Прекратить существование** — үлү; бетү.

**СУЩЕСТВОВА'ТЬ** *несов.* — 1. яшәү, яшәп килү; 2. булу, гамәлдә булу; 3. яшәү, көн күрү; *существовать своим трудом* — үз хезмәтең белән көн күрү.

**СУ'ЩИЙ** — 1. (*существующий*) булган; яшәп килә торган; 2. *перен. разг.* чын, чып-чын; *сущая правда* — чын хакыйкать. ◇ **Сущее наказание** — к. наказание. **Сущий пустяк** или **сущая безделица** — зур нәрсә түгел; вак нәрсә; зур эш түгел; бик жиңел эш.

**СУ'ЩНОСТЬ** *ж. мн.* нет — асыл; нигез; төп нигез. ◇ **В сущности** или **в сущности говоря** *ввод. сл.* — асылда, нигездә, чынында.

**СУЯ'ГНАЯ** *с.-х.* — буаз (сарык турында).

**СФАБРИКОВА'ТЬ** *сов.* — к. фабриковать 3.

**СФА'ГНУМ** *м. мн.* нет — сфагнум (1. *бот.* мүкнең бер төре; 2. *спец.* шул мүктән барлыкка килгән торф; 3. *тех.* шул торфтан әзерләнгән изоляцион материал).

**СФАЛЬШИ'ВИТЬ** *сов.* — к. фальшивить.

**СФАНТАЗИ'РОВАТЬ** *сов.* — к. фантазировать 2.

**СФЕ'РА** *ж.* — 1. *мат.* сфера, шар; 2. *перен. книж.* сфера, өлкә; *научный интерес в определённой сфере знаний* — фәннең билгеле бер өлкәсендә гыйльми кызыксыну; 3. *перен. книж.* среда, мохит, сфера, тирә-юнь; *в своей сфере* — үз сферасында. ◇ **Высшие сферы** *книж. устар.* — югары даирәләр. **Небесная сфера** *астр.* — күк йөзе.

**СФЕРИ'ЧЕСКИЙ** *мат. спец.* — 1. шарсыман, шарга охшашлы; *сферическое тело* — шарсыман җисем; 2. сферик; *сферическая геометрия* — сферик геометрия.

**СФЕРО'ИД** *м. мат.* — сфероид (ике ягыннан бераз кысылган шар).

**СФЕРОИДА'ЛЬНЫЙ** *мат. физ.* — сфероидаль, сфероид формалы, сфероидка охшашлы.

**СФЕРО'МЕТР** *м. физ.* — сферометр (оптик пыялаларның кәкрелек радиусын үлчәү приборы).

**СФИГЛЯ'РИТЬ** *сов. разг.* — к. фиглярить.

**СФИГЛЯ'РНИЧАТЬ** *несов. разг.* — к. фиглярничать.

**СФИ'НКС** *м.* — сфинкс (1. борынгы Мисырда башын кеше башына охшатып таштан ясалган арслан сыны; 2. борынгы грекларда — башы белән күкрәге хатын-кызларга, гәүдәсе арсланга яки эткә охшатып ясалган канатлы хайван; 3. *перен. книж.* билгесез бер серле нәрсә; 4. *зоол.* Африкада яшәүче маймылларның бер төре; 5. күбәләкнең бер төре).

**СФОРМИРОВА'ТЬ** *сов.* — к. формировать.

**СФОРМИРОВА'ТЬСЯ** *сов.* — к. формироваться 1, 2.

**СФОРМОВА'ТЬ** — к. формовать.

**СФОРМОВА'ТЬСЯ** *сов.* — к. формоваться.

**СФОРМУЛИ'РОВАТЬ** *сов.* — к. формулировать.

**СФОРЦА'НДО** *нареч. муз.* — сфорцандо (билгеле бер авазга басым ясап).

**СФОТОГРАФИ'РОВАТЬ** *сов.* — к. фотографировать.

**СФОТОГРАФИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* — к. фотографироваться 1.

**СФРАГИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *науч.* — сфрагистика (мөһерләрне өйрәнә торган ярдәмче тарихи дисциплина).

**СФУГОВА'ТЬ** *сов. стол.* — к. фуговать.

**СФУГО'ВЫВАТЬ** *несов. стол.* — к. фуговать.

**СФУГО'ВЫВАТЬСЯ** *несов. страд. стол.* — к. фуговаться.

**СХА'ПАТЬ** *сов. простореч.* — к. хапать 1, 2.

**СХВАТ** *м. спец.* — 1. *обл.* к. схватка 3; 2. *только мн. обл.* келәшчә, каргаборын; кыскыч.

**СХВАТИ'ТЬ** *сов.* — 1. эләктереп алу, тотып алу; 2. *разг.* (авыру) эләктерү, (авыру) йоктыру; *схватить лихорадку* — бизгәк эләктерү; 3. *разг.* авырып китү; (авыру) тота башлау; *его схватила лихорадка* — аны бизгәк тота башлады; 4. *перен. разг. усвоить)* төшенү, аңлап алу, хәтердә калдыру; 5. *простореч.* эләктерү, эләктереп кую; тоташтыру; *схватить брёвна скобой* — бүрәнәләрне атлама белән эләктереп кую; 6. *спец.* беркетү; *цемент хорошо схватил камни* — цемент ташларны яхшы беркетте; 7. *безл. спец.* кату; *цемент хорошо схватило* — цемент яхшы катты. ◇ **Схватить простуду** — салкын тидерү.

**СХВАТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тотыну; тоту; *схватиться за саблю* — кылычка тотыну; *схватиться за голову* — башны тоту; 2. берберсен эләктереп алу; *борцы схватились* — көрәшчеләр бер-берсен эләктереп алдылар; 3. *простореч.* сикереп тору; *схватиться с постели* — урыннан сикереп тору.

**СХВА'ТКА** *ж.* — 1. бәрелеш; 2. *преимущ. мн.* тулгак тоту; 3. *спец. обл.* тоташкан урын; 4. *только мн. спец.* эләктергеч, каптыргыч; каптырма.

**СХВА'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. схватить.

**СХВА'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. схватиться; 2. *страд.* тотып алыну, эләктереп алыну.

**СХЕ'МА** *ж.* — 1. схема; чертёж, сызым; *схема радиоприёмника* — радиоалгычның схемасы; 2. схема, кыскача план; *схема доклада* — докладның кыскача планы; 3. *перен. пренебр.* схема, форма; *мыслить готовыми схемами* — әзер схемалар буенча фикерләү.

**СХЕМАТИЗА'ТОР** *м. книж.* — схемалаштыручы.

**СХЕМАТИЗИ'РОВАТЬ** *сов. и несов. книж.* — схемалаштыру, схема рәвешендә бирү; схемасын бирү.

**СХЕМАТИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — схемалаштырылу, схема рәвешендә бирелү; схемасы бирелү.

**СХЕМАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — схематизм, схемачылык (әзер схемалар буенча гына фикер йөртү).

**СХЕМАТИ'ЧЕСКИЙ** — схематик, схема рәвешендә бирелгән.

**СХЕМАТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, — схема рәвешендә булу, схема рәвешендә бирелгән булу.

**СХЕМАТИ'ЧНЫЙ** — к. схематический.

**СХИ'ЗМА** *ж. мн.* нет, *церк.* — схизма, ересь, раскол.

**СХИЗМА'ТИК** *м. церк.* — схизматик, еретик, раскольник.

**СХИЗМАТИ'ЧЕСКИЙ** *церк.* — схизматик.

**СХИЗМАТИ'ЧКА** *ж. церк.* — схизматичка, еретичка.

**СХИ'МА** *ж. мн.* нет, *церк.* — схима (иң югары монахлык дәрәҗәсе).

**СХИ'МНИК** *м. церк.* — схимник, схима кабул иткән монах.

**СХИ'МНИЦА** *ж. церк.* — схимница, схима кабул иткән монашка.

**СХИ'МНИЧЕСКИЙ** *церк.* — схимниклык ...-ы, схимник ...-ы; *схимническая жизнь* — схимник тормышы.

**СХИ'МНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *церк.* — схимниклык.

**СХИМОНА'Х** *м. церк.* — к. схимник.

**СХИМОНА'ХИНЯ** *ж. церк.* — к. схимница.

**СХИМОНА'ШЕСКИЙ** *церк.* — к. схимнический.

**СХИТРИ'ТЬ** *сов.* — хәйләләү, хәйләләп алу, хәйләләп кую.

**СХЛЕБА'ТЬ** *сов простореч.* — 1. (эчеп, ашап) киметә төшү; чөмереп алу; 2. ашап бетерү (сыек ашны).

**СХЛЁБЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. схлебать.

**СХЛЕСТА'ТЬ** *сов. просторечи.* — (чыбыркы, чыбык белән) сугып өзү, сыдырып өзү.

**СХЛЕСТНУ'ТЬ** *сов. простореч.* — (чыбыркы, чыбык белән) сугып өзү, сыдырып өзү.

**СХЛЕСТНУ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — чәбәләнү.

**СХЛЁСТЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. схлестать, схлестнуть.

**СХЛЁСТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. схлестнуться; 2. *страд.* (чыбыркы, чыбык белән) сугып өзелү, сыдырып өзелү.

**СХЛОПОТА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — юллап алу, (берәр эшне) юллап чыгару.

**СХЛЫ'НУТЬ** *сов.* — 1. кире агып китү; кире китү; кире кайту, чигү; *вода схлынула с берега* — су ярдан кире агып китте (кире кайтты); 2. кимү, азаю; *к вечеру толпа на улицах схлынула* — кичкә таба урамнарда халык төркеме кимеде; 3. *перен.* (бик тиз) бетү, юкка чыгу, юк булу; *страх мгновенно схлынул, надежда также мгновенно превратилась в уверенность* (Короленко) — курку күз ачып йомганчы бетте, өмет тә шулай ук бик тиз арада нык ышанычка әверелде.

**СХОД** *м.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. сойти I в 1,5 *знач*; 2. *только ед.* (*действие* к. сойтись 2; 3. *разг.* төшә торган (урын) юл; *крутой сход* — төшә торган юл бик текә; 4. *устар.* сход, җыен; *сельский сход* — авыл җыены.

**СХО'ДБИЩЕ** *ср. устар., теперь неодобр.* — җыен, җыелган халык төркеме.

**СХО'ДЕНЬ** *м. обл.* — к. сходни.

**СХОДИ'ТЬ** I *сов.* — 1. барып кайту, барып килү; *сходить посмотреть новое здание* — яңа бинаны барып карап кайту; 2. тышка чыгу.

**СХОДИ'ТЬ** II *несов.* — к. сойти.

**СХОДИ'ТЬСЯ** *несов.* — к. сойтись.

**СХО'ДКА** *ж.* — сходка, җыен.

**СХО'ДНИ** *мн.* — басма (мәсәлән, көймәдән, пароходтан ярга чыгар өчен).

**СХО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *простореч.* — (бәя ягыннан) яраклы булу, кыйбат булмау.

**СХО'ДНЫЙ** — 1. охшаш, үзара охшаш; *сходные выражения* — үзара охшаш тәгъбирләр; 2. *простореч.* кыйбат булмаган; кулай, яраклы; *сходный товар* — кыйбат булмаган товар.

**СХО'ДСТВЕННЫЙ** *устар.* — к. сходный 1.

**СХО'ДСТВО** *ср. мн. нет* — охшашлык, охшаш булу.

**СХО'ДСТВОВАТЬ** *несов. устар.* — охшашу, охшаш булу.

**СХО'ЖЕСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — к. сходство.

**СХО'ЖИЙ** — 1. *разг.* к. сходный 1; 2. *простореч. устар.* төрле яктан җыелган; *схожий народ* — төрле яктан җыелган халык.

**СХОЛА'СТ, СХОЛА'СТИК** *м.* — схоласт (1. *истор.* урта гасырларда схоластиканы яклаучы галим; 2. *книж.* схоластик фәлсәфәгә бирелгән кеше, коры фәлсәфә белән мавыгучы кеше).

**СХОЛА'СТИКА** *ж.* — схоластика (1. *филос. истор.* урта гасырларда дин догмаларына нигезләнеп философик система төзегән, чынбарлыктан ерак булган идеалистик философиянең гомуми исеме; 2. *книж.* тормыш һәм практикадан ерак булган, тәҗрибәдә тикшерелмәгән белем, коры фәлсәфә, мәгънәсез бәхәсләшү).

**СХОЛАСТИ'ЧЕСКИЙ** — схоластик, схоластикага нигезләнгән; *схоластическая философия* — схоластик философия.

**СХОЛАСТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. схоластический.

**СХОЛИА'СТ** *м. книж.* — комментатор, аңлатма бирүче, шәрехләүче.

**СХО'ЛИЯ** *ж. книж.* — комментарий, (текстка) аңлатма.

**СХОРОНИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* к. похоронить; 2. *простореч.* яшерү, яшереп кую; 3. *перен.* әрәм итү, харап итү, һәлак итү.

**СХОРОНИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. схорониться 1.

**СЦА'ПАТЬ** *сов.* — 1. *простореч.* (*взять, схватить*) эләктерү, эләктереп алу; 2. *обл.* чәлдерү (урлау мәгънәсендә).

**СЦА'ПАТЬСЯ** *сов. простореч., обл.* — бәрелешеп алу, талашып алу, әрләшеп алу.

**СЦАРА'ПАТЬ** *сов. разг.* — тырнап алу, кырып алу, кырып чистарту.

**СЦАРА'ПНУТЬ** *однокр. разг.* — тырнап алу.

**СЦАРА'ПЫВАТЬ** *несов.* — к. сцарапать.

**СЦАРА'ПЫВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* —

тырнап алыну, кырып алыну, кырып чистартылу.

**СЦЕДИ'ТЬ** *сов.* — агызу, агызып алу, сөзеп алу, саркыту, саркытып алу.

**СЦЕ'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. сцедить.

**СЦЕ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — агызылу, агызып алыну, сөзеп алыну, саркытылу, саркытып алыну.

**СЦЕ'НА** *ж.* — **1.** сәхнә; *вращающаяся сцена* — әйләнә торган (әйләнмә) сәхнә; **2.** *только ед. перен.* сәхнә, театр; *полвека на сцене* — ярты гасыр (илле ел) сәхнәдә (уйнау); **3.** күренеш; *действие второе, сцена четвертая* — икенче пәрдә, дүртенче күренеш (пьесада); **4.** вакыйга, күренеш, эпизод; *сцена прощания в романе Л. Толстого „Воскресение"* — Л. Толстойның „Янадан туу" дигән романында саубуллашу күренеше (эпизоды); **5.** *перен. разг.* орышталаш, җәнҗал, кычкырыш; *устраивать сцены* — җәнҗал чыгару; **6.** *перен. книж.* мәйдан, эшчәнлек мәйданы; *пролетариат выступает на сцену как активный строитель новой жизни* — пролетариат яңа тормышның актив төзүчесе буларак мәйданга чыга.

**СЦЕНА'РИЙ** *м.* — сценарий (**1.** *театр.* пьесада катнашучыларның сәхнәгә чыгу тәртибен һәм вакытын күрсәтеп язылган исемлек; **2.** *театр.* драматик әсәрнең, пьесаның планы; **3.** кинофильмның җентекләп язылган эчтәлеге).

**СЦЕНАРИ'СТ** *м.*, **СЦЕНАРИ'СТКА** *ж.* — сценарист, сценарий авторы.

**СЦЕНА'РИУС** *м. театр.* — сценариус (театрда актёрларның сәхнәгә чыгу тәртибен күзәтүче работник).

**СЦЕНИ'ЧЕСКИЙ** — **1.** сәхнә ...-ы; *сценическое оформление* — сәхнә оформлениесе; **2.** сәхнәдә ...; *сценическая деятельность* — сәхнәдә эшләү; **3.** к. сценичный.

**СЦЕНИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет. — сәхнә өчен яраклылык, сәхнә өчен яраклы булу.

**СЦЕНИ'ЧНЫЙ** — сәхнә өчен яраклы.

**СЦЕП** *м. спец.* — **1.** *только ед. (действие)* к. сцепить; **2.** эләктергеч, тоташтыргыч, ыргак; *вагонные сцепы* — вагон эләктергечләре; **3.** икесе бергә тоташтырылган тимер юл платформасы, икесе бергә тоташтырылган авыл хуҗалыгы машинасы (мәсәлән, ике комбайн).

**СЦЕПИ'ТЬ** *сов.* — тагу, эләктерү, эләктереп кую, тоташтыру.

**СЦЕПИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** тоташу; эләгү; эләктерелү; *по небрежности сцепщика вагоны не сцепились как следует* — вагоннар тоташтыручының игътибарсызлыгы аркасында вагоннар тиешенчә эләктерелмәгәннәр; **2.** бәрелеп эләгү; *встречные экипажи сцепились* — каpa-каршы килгән экипажлар бәрелеп эләккәннәр; **3.** укмашу; *репья сцепились в комок* — кырмавыклар йомгак булып укмашканнар.

**СЦЕ'ПКА** *ж. спец.* — к. сцеп.

**СЦЕПЛЕ'НИЕ** *ср.* — **1.** *только ед. (действие)* к. сцепить; **2.** *только ед.* к. сцепиться **1, 2**; **3.** *перен.* бергә туры килү, бергә туплану, тупланыш; *случайное сцепление обстоятельств* — вакыйгаларның очраклы рәвештә бергә тупланышы.

**СЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. сцепить.

**СЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. сцепиться; **2.** *страд.* тоташтырылу, эләктереп куелу.

**СЦЕПНО'Й** *спец.* — тоташтырылган, тоташтырыла торган.

**СЦЕ'ПЩИК** *м.* — вагоннар тоташтыручы (тимер юлда вагоннарны тоташтыру эшендәге тимер юл эшчесе).

**СЧА'ЛИВАТЬ** *несов.* — к. счалить.

**СЧА'ЛИВАТЬСЯ** *несов.* — **1.** *спец.* к. счалиться; **2.** *страд.* бәйләнү, бергә бәйләнү, бәйләп куелу, элмәкләп куелу.

**СЧА'ЛИТЬ** *сов.* — **1.** *спец.* бәйләү, бергә бәйләү, бәйләп кую; элмәкләп бәйләү; *счалить плоты* — салларны бергә бәйләү; **2.** *обл., вульг.* чәлдерү (урлау мәгънәсендә).

**СЧА'ЛИТЬСЯ** *сов. спец.* — бергә бәйләнү, элмәкләп бәйләнү.

**СЧАСТЛИ'ВЕЦ** *м.* — бәхетле кеше.

**СЧАСТЛИ'ВИТЬ** *сов. устар. редко* — **1.** к. осчастливить; **2.** *безл.* к. счастливиться.

**СЧАСТЛИ'ВИТЬСЯ** *несов. безл.* — (эше) уңу, (эше) барып чыгу, бәхете булу.

**СЧАСТЛИ'ВИЦА** *ж.*, **СЧАСТЛИ'ВЧИК** *м. разг. фам.* — к. счастливец.

**СЧАСТЛИ'ВЫЙ** — **1.** бәхетле; *счастливый человек* — бәхетле кеше; **2.** бәхетле, уңышлы; *счастливая мысль* — уңышлы фикер; *выдался счастливый день* — бәхетле көн туры килде; **3.** бәхет ...-ы, бәхетлелекне белдерә торган, бәхетле икәнлеген белдерә торган. ◇ **Счастлив твой бог!** *разг. устар.* — бәхетең бар икән! **Счастливо оставаться!** — сау булыгыз! Хушыгыз! **Счастливо отделаться** от *кого-чего* — җиңел котылу. **Счастливого пути!** — Хәерле юл! Ак юл! Юлың ак булсын!

**СЧА'СТЬЕ** *ср. мн.* нет — бәхет. ◇ **Иметь счастье** — бәхеткә каршы. **К** (моему, твоему и т. д.) **счастью** или **к счастью** (для меня, тебя и т. д.) или **на** (моё, твоё и т. д.) **счастье** — бәхетемә (бәхетеңә) каршы. **На счастье** *чьё* — бәхетеңә, бәхете булсын өчен. **По счастью** — бәхеткә каршы. **Счастье моё** (твоё, его и т. д.), *что* ...-бәхетемә (бәхетеңә һ. б.) каршы ..., бәхете (м. н).

**СЧЕКА'НИВАТЬ** *несов. спец.* — к. счеканить.

**СЧЕКА'НИТЬ** *сов. с.-х.* — (җимешләре тизрәк өлгерсен өчен) үсемлекнең өске ботакларын кисеп ташлау.

**СЧЕ'РПАТЬ** *сов.* — бераз сосып алу; өстеннән җыеп алу (мәсәлән, сөтнең каймагын).

**СЧЕРПНУ'ТЬ** *сов.* — к. счерпать.

**СЧЕ'РПЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — бераз сосып алыну; өстеннән җыеп алыну (мәсәлән, сөтнең каймагы турында).

**СЧЕРТИ'ТЬ** *сов. разг.* — күчереп сызу, сызып күчермәсен алу (мәсәлән, чертёжның, планның һ. б.).

**СЧЕ'РЧИВАТЬ** *несов. разг.* — к. счертить.

**СЧЕ'РЧИВАТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — күчереп сызылу, (сызып) күчермәсе алыну.

**СЧЁС** *м. мн.* нет — **1.** *спец. (действие)*

к. счесать 1; 2. *спец.* тарап алынган нәрсә; 3. *обл.* тырнап ертылган урын, тырналган урын.

**СЧЕСА'ТЬ** *сов.* — 1. тарап чистарту, тарап алу; *счесать пух с сукна* — сукноның мамыгын тарап алу; 2. *разг.* тырнап ерту, тырнап алу.

**СЧЕСА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тарап алыну, чистару; 2. тырнап алыну, тырнап ертылу.

**СЧЁСКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. счёс 1.

**СЧЕСТЬ** *сов.* — к. считать 1 в 1, 3 знач. ◇ **Дни сочтены** *книж.* — көннәре санаулы, үлемгә якынлашкан.

**СЧЕ'СТЬСЯ** *сов.* — к. считаться 1, 2.

**СЧЁСЫВАТЬ** *несов.* — к. счесать.

**СЧЁСЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. счесаться; 2. *страд.* тарап чистартылу, тарап алыну.

**СЧЁТ** *м.* — 1. санау, исәпләү; исәп, сан; 2. *только ед.* исәп; *футбольный матч окончен со счётом 2:1* — футбол матчы 2:1 исәбе белән тәмамланды; 3. счёт; *официант подал счёт* — официант счёт бирде; *текущий счёт* — агымдагы счёт; 4. чут, счёт. ◇ **Без счёту** — исәпсез-хисапсыз, бик күп. **В два счёта** — к. два. **В конечном** или **последнем счёте** — нәтиҗәдә. **В счёт** *чего* (выдать, получить и т. п.) *канц.* — исәбенә; *выдать деньги в счёт гонорара* — гонорар исәбенә акча бирү. **За счёт** *кого-чего* — исәбенә. **Личные счёты** *у кого с кем* — үзара исәп-хисап; үзара аңлашылмаулар. **На свой счёт принять** — к. принять. **На счёт** *кого-чего* или *чей* — (берәр кешенең) исәбенә. **На счёт** *кого-чего* или *чей* **счёт говорить** (думать и т. п.) — (берәр кеше) турында сөйләү (уйлау һ. б.). **На счету** — исәптә. **Быть на хорошем** (или **плохом**) **счету** — яхшылар (начарлар) исәбенә кертелү, яхшылардан (начарлардан) саналу. **Не в счёт** *разг.* — саналмый, исәпкә алынмый. **Не в счёт абонемента** *разг. фам.* — ...-дан тыш. **Покончить счёты с** *кем-чем* — 1. исәп-хисапны өзү, өзелешү, исәп-хисапны бетерү; 2. *перен.* өзелешү, ара өзелү, аерылу. **По счёту первый** (второй, третий и т. п.) — беренче (икенче, өченче һ. б.). **Свести счёты** с *кем-чем* — 1. (берәү белән) исәп-хисапны өзү, өзелешү, исәп-хисапны бетерү; 2. *перен.* үч алу. **Счёту нет** *кому-чему* или **без счёту** *кого-чего разг.* — исәпсез-хисапсыз, бик күп. **Со счётов сбросить** (скинуть) *перен.* — исәптән чыгарып ташлау, исәпкә алмый башлау. **Терять** (потерять) **счёт** *кому-чему* — бик күп, санап бетергесез. **Что за счёты** *разг.* — санап тору нигә кирәк, санашып тору нигә кирәк.

**СЧЕТВЕРИ'ТЬ** *сов.* — дүртен бергә кую, дүртен бергә кушу; дүрт итеп кую.

**СЧЁТНЫЙ** — 1. хисаплау ...-ы, санау ...-ы; *счётная машина* — хисаплау машинасы; 2. к. счетоводный.

**СЧЕТОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.* — к. счетоводство.

**СЧЕТОВО'Д** *м.* — счетовод, хисапчы.

**СЧЕТОВО'ДНЫЙ** — исәп-хисап ...-ы, хисап ...-ы, хисап алып бара торган; *счетоводные книги* — исәп-хисап кенәгәләре.

**СЧЕТОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — хисапчылык.

**СЧЕТОВО'ДЧЕСКИЙ** — хисапчылык ...-ы, хисапчылар ...-ы; *счетоводческие курсы* — хисапчылар курсы.

**СЧЁТЧИК** *м.* — 1. санаучы, исәпләүче (кеше); 2. счётчик (электр энергиясен, газны һ. б. тотуны исәпли торган прибор)

**СЧЁТЧИЦА** *ж.* — к. счётчик 1.

**СЧЁТЫ** *только мн.* — счёт, чут (төймәле счёт).

**СЧИСЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. счёт 1.

**СЧИ'СЛИТЬ** *сов. устар., простореч.* — санау, исәпләү, исәпләп чыгару.

**СЧИСЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. счислить.

**СЧИСЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. устар. простореч.* — саналу, исәпләнү, исәпләп чыгарылу.

**СЧИ'СТИТЬ** *сов.* — чистарту, тазарту, арчу; китәрү.

**СЧИ'СТИТЬСЯ** *сов.* — чистару, тазару, арчылу.

**СЧИТА'ТЬ** I *несов.* — 1. санау; *считать деньги* — акча санау; *считай: раз, два три — и беги* — бер, ике, өч дип сана да йөгер; 2. *(вести начало чему-н. от кого-чего-н.)* исәпли башлау; 3. исәпләү, хисаплау, санау, уйлау; *Максима считали умершим* — Максимны үлгән дип уйлыйлар иде; *его считают знатоком в этой области* — аны бу өлкәдә белгеч дип саныйлар; *считаю, что он прав* — ул хаклы дип уйлыйм. ◇ **Не считая** — санамыйча, исәпкә алмыйча. **Считанные дни** (остались) – санаулы көннәр (калды), бик аз вакыт (калды), **Считать ворон** — к. ворона. **Считать звёзды** *разг. фам.* — авыз ачып тору. **Считать мух** — авыз ачып тору.

**СЧИТА'ТЬ** II *сов.* — чагыштырып уку, чагыштырып укып чыгу; *считать гранки с рукописью* — гранкаларны кулъязма белән чагыштырып уку.

**СЧИТА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *(расплачиваться)* түләп бетерү, исәп-хисапны өзү; 2. *перен. простореч.* санашу, сүз көрәштерү, талашу, сүзен бирмәү; *он со всяким считается* — ул теләсә кем белән сүз көрәштерә; 3 исәпләшү, санашу, санга сугу, игътибарга алу, санга алу, исәпкә алу; *с ним надо считаться* — аның белән исәпләшергә кирәк; 4. *страд.* саналу, исәпләнү, исәпкә алыну.

**СЧИ'ТЧИК** *м.*, **СЧИ'ТЧИЦА** *ж. спец.* — чагыштырып укучы (типография, нәшрият эшчесе).

**СЧИ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. считать II.

**СЧИ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — чагыштырып укылу.

**СЧИЩА'ТЬ** *несов.* — к. счистить.

**СЧИЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. счиститься; 2. *страд.* чистартылу, тазартылу; арчылу.

**СШИБА'ТЬ** *несов. разг.* — к. сшибить.

**СШИБА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. сшибиться; 2. *страд.* бәреп төшерелү, сугып төшерелү; бәреп егылу, сугып егылу.

**СШИБИ'ТЬ** *сов. разг.* — 1. бәреп төшерү, сугып төшерү; *сшибить шапку* — бү-

рекне баштан бәреп төшерү; 2. бәреп егу, сугып егу; *сшиб прохожего с ног* — узып баручыны аяктан бәреп екты; 3. *перен.* сындыру; бетерү; *гордость-то, гордость-то ему сшибить надо* (А. Островский) — тәкәбберлеген, тәкәбберлеген бетерергә кирәк аның.

**СШИБИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — 1. *(столкнуться)* килеп бәрелешү, бер-берсенә барып бәрелү; 2. *устар. (вступить в бой)* бәрелешү, сугыша башлау, сугышу; 3. *фам. (затеять спор)* бәрелешү, бәхәсләшә башлау, сүз көрәштерә башлау.

**СШИВА'ТЬ** *несов.* — к. сшить 2.

**СШИВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. тегелү, тектерелү; 2. тегелү, җөйләнү; ялгану, ялгап куелу.

**СШИ'ВКА** *ж. спец. разг.* — 1. *только ед. (действие)* к. сшить 2; 2. җөй, тегелгән урын; *разорвалось на сшивке* — җөеннән ертылды.

**СШИВНО'Й** — ике кисәктән тегелгән, җөйле (бөтен түгел).

**СШИ'ТЫЙ** — тегелгән. ◇ **Крепко сшитый** *(о человеке) перен.* — нык, таза (кеше).

**СШИТЬ** *сов.* — 1. тегү, тектерү; *сшить костюм* — костюм тегү; 2. тегү, җөйләү, (тегеп) ялгау, (тегеп) ялгап кую, тегеп кую; *сшить два куска материи* — ике кисәк материяне ялгау.

**СШУТИ'ТЬ** *сов. простореч.* — шаярту, шаяртып алу.

**СЪЕДА'ТЬ** *несов.* — к. съесть.

**СЪЕДА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — ашалу, ашап бетерелү.

**СЪЕДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет: **отдать на съедение** *перен.* — (берәүнең) ихтыярына бирү, (берәүгә) тапшыру, измәсен изәргә бирү, өзгәләп бетерергә бирү.

**СЪЕДО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ашый торган булу, ашарга ярый торган булу; 2. ашарлык булу.

**СЪЕДО'БНЫЙ** — 1. ашый торган, ашарга ярый торган; *съедобные грибы* — ашарга ярый торган гөмбәләр; 2. *разг. фам.* ашарлык; *щи съедобные* — щи ашарлык.

**СЪЁЖИВАТЬ** *несов.* — к. съёжить.

**СЪЁЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. съёжиться; 2. *страд.* җыерылу, җыелу.

**СЪЁЖИТЬ** *сов.* — җыеру, бөрештерү, җыю.

**СЪЁЖИТЬСЯ** *сов.* — бөгәрләнү; бөрешү; корышу; йомарлану; куырылу.

**СЪЕЗД** I *м.* — 1. *только ед. (действие)* к. съехаться; 2. съезд; *съезд профсоюзов* — профсоюзлар съезды; *XXI съезд Коммунистической партии Советского Союза* — Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXI съезды.

**СЪЕЗД** II *м.* — 1. *только ед. (действие)* к. съехать 1, 2; 2. төшү урыны, түбәнгә төшә торган юл.

**СЪЕ'ЗДИТЬ** *сов.* — 1. (атка, трамвайга, автобуска һ. б. утырып) барып кайту, барып килү; *съездить в магазин* — магазинга барып кайту; 2. *простореч. вульг.* утырту, бирү, кундыру, менеп төшү (бик нык сугу мәгънәсендә); *съездить кому-н. по физиономии* — яңагына берне утырту, яңагына берне бирү. ◇ **Съездить в Ригу** *разг. вульг.* — косу.

**СЪЕ'ЗДОВСКИЙ** — съезд ...-ы; *съездовские резолюции* — съезд резолюцияләре.

**СЪЕЗЖА'ТЬ** *несов.* — к. съехать.

**СЪЕЗЖА'ТЬСЯ** *несов.* — к. съехаться.

**СЪЕ'ЗЖАЯ** *ж. истор.* — съезжий (полиция участогы, кулга алынганнарны ябып тоту өчен полиция карамагындагы бина).

**СЪЕ'ЗЖИЙ** *устар.* — 1. төрле яктан килгән, төрле яктан җыелган; *съезжий народ* — төрле яктан җыелган халык; 2. халык җыела торган, халык туплана торган; *съезжая площадь* — халык җыела торган мәйдан.

**СЪЁМ** *м. мн.* нет, *простореч.* — к. съёмка 1.

**СЪЁМКА** *ж.* — 1. *только ед. (действие)* к. снять 1, 7, 8, 9, 17; 2. *спец.* (планга, картага) төшереп алу, съёмка; *инструментальная съёмка* — инструментлар ярдәмендә ясалган съёмка.

**СЪЁМНИК** *м. спец.* — алгыч, салдыргыч; *колёсные съёмники* — тәгәрмәч салдыргычлар.

**СЪЁМНЫЙ** *спец.* — алынмалы, алына торган, салдырыла торган; *съёмная крышка* — алына торган капкач.

**СЪЁМОЧНЫЙ** *спец.* — съёмка ...-ы, (планга, картага) төшереп алу ...-ы; *съёмочные работы* — (планга, картага) төшереп алу эшләре, съёмка эшләре.

**СЪЁМЦЫ** *только мн. устар. обл.* — кыскыч (шәм көйреген алып ташлый торган кыскыч).

**СЪЁМЩИК** *м.*, **СЪЁМЩИЦА** *ж.* — (вакытлыча файдалануга) алып торучы; *съёмщик квартиры* — квартир алып торучы.

**СЪЕСТНО'Е** *ср. в знач. сущ.* — ашамлык әйберләре, ашамлыклар, азык, азык-төлек.

**СЪЕСТНО'Й**: **съестные припасы** — ашамлык запаслары.

**СЪЕСТЬ** *сов.* — 1. ашау, ашап бетерү; *съесть тарелку супу* — бер тәлинкә шулпа ашау; 2. *перен. простореч.* җан ашау, чәйнәп бетерү, теңкә корытып бетерү, теңкәгә тиеп бетү; *тёща совсем съела его* — каенанасы аның теңкәсен корытып бетерде; 3. *простореч. фам.* йоту, юлдан алып ташлау, юкка чыгару, һәлак итү; башын ашау, башына житү; *он съел своего конкурента* — ул үзенең конкурентын юлдан алып ташлады; 4. *перен. простореч. фам.* (берәр төрле хурландыра торган сүзне яки хурлап әйткән сүзне) җавапсыз калдыру, эндәшми калу; каршы сүз әйтмәү, каршы бер сүз дә әйтмәү; *съесть дурака* — „тиле" дигән сүзгә каршы бер сүз дә әйтмәү; 5. *обл. спец. (сточить, стереть)* ашау, кыру. ◇ **Собаку съесть** — к. собака.

**СЪЕ'ХАТЬ** *сов.* — 1. (атка, машинага утырып) төшү; *съехать с горы* — (берәр нәрсәгә утырып) таудан төшү; 2. *разг.* шуып төшү; *съехал на ногах с ледяной горы* — боз тавыннан аягүрә басып шуып

төште; 3. китү, күчеп китү, (өйдән, квартирдан) чыгу; чыгып китү; *съехать с квартиры* — квартирдан чыгу; 4. *перен.* төшү, салынып төшү; *шапка съехала ему на ухо* — бүреге колагына төшкән; 5. *перен. простореч. фам.* төшү, (хак) киметү; *со ста рублей съехал на двадцать* — йөз сумнан егерме сумга төште. ◇ **Съехать на берег** *мор.* — ярга чыгу.

**СЪЕ'ХАТЬСЯ** *сов.* — 1. (атта, машинада һ. б. барганда) очрашу; 2. (атка, машинага, поездга һ. б. утырып килеп) җыелу, төрле яктан җыелу.

**СЪЕХИ'ДНИЧАТЬ** *сов. разг.* — мыскыллап алу, мыскыллап көлеп алу, чәнчеп алу, чәнчүле сүз әйтү, йөрәгенә кадау (каты авыр сүз белән).

**СЪЯ'БЕДНИЧАТЬ** *сов. простореч.* — к. язябедничать.

**СЫ'ВОРОТКА** *ж.* — 1. май әйрәне, гөбе әйрәне; 2. сары су, эремчек (сөзмә) суы; 3. *мед.* сыворотка (дәвалау һәм диагноз кую чарасы).

**СЫ'ГРАННОСТЬ** *ж. мн.* нет — бергәләп уйнарга күнегеп җитү, бергәләп уйнарга күнегеп җиткәнлек.

**СЫ'ГРАННЫЙ** — 1. уйналган; башкарылган; 2. *только полной ф-мы разг.* бергәләп уйнарга остарып җиткән, бергәләп уйнарга күнегеп җиткән.

**СЫГРА'ТЬ** *сов.* — уйнау, уйнап алу; башкару; *сыграть на скрипке* — скрипкада уйнау; *сыграть большую роль в чём-н.* — (берәр нәрсәдә) зур роль уйнау. ◇ **Сыграть шутку или штуку** *с кем-чем* — шаяртып мыскыллау, шаяртып көлү, берәр күңелсезлек эшләү. **Сыграть в великодушие** — киң күңеллелек күрсәтеп маташкан булу, киң күңеллелек күрсәткән булып маташу. **Сыграть на руку** *кому-н.* — (берәр кешенең) файдасына эшләү.

**СЫГРА'ТЬСЯ** *сов.* — бергәләп уйнарга остарып җитү, бергәләп уйнарга күнегеп җитү.

**СЫ'ГРЫВАТЬСЯ** *несов.* — к. сыграться.

**СЫЗДЕ'ТСТВА** *нареч. простореч.* — балачактан бирле, балачактан.

**СЫ'ЗМАЛА, СЫ'ЗМА'ЛЬСТВА** *нареч. простореч.* — кечедән, кечкенәдән, кечкенәдән бирле, кече яшьтән бирле.

**СЫ'ЗНОВА** *нареч. разг.* — яңадан, яңа баштан.

**СЫМА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. снимать.

**СЫМА'ТЬСЯ** *несов. простореч* — к. сниматься.

**СЫН** *м.* — 1. (*мн.* сыновья) ул; *у меня два сына, одна дочь* — минем ике улым, бер кызым бар; *сын трудового народа* — хезмәт халкының улы; 2. *ритор.* (*мн.* сыны) уллар (киләчәк буын).

**СЫНО'ВНИЙ** — уллык ...-ы; улның ата-анага булган, улның ата-ана каршындагы; *сыновний долг* — улның ата-ана каршындагы бурычы.

**СЫ'ПАТЬ** *несов.* — 1. тутыру, салу; *сыпать пшеницу в мешок* — капчыкка бодай тутыру; 2. *разг.* сибү; *сыпать песком* — ком сибү; 3. *перен. разг.* яудыру; *сыпать остротами* — тапкыр сүзләр яудыру; 4. *перен., простореч. фам.* элдертү (бик тиз бару, йөгерү турында); *сыпь домой* — өйгә элдерт. ◇ **Сыпать деньгами** *разг.* — акча туздыру, акча әрәм-шәрәм итү, акчаны җилгә очыру.

**СЫ'ПАТЬСЯ** *несов.* — 1. коелу, коелып төшү; *сверху сыпались листья* — өстән яфраклар коела иде; 2. *перен. разг.* (төрле яктан) яву; *сыплются обвинения* — төрле яктан гаепләү сүзләре (гаепләүләр) ява; 3. сыпылу, сизрәү (иске тукыма турында); коелу (чите киселгән тукыманың җепләре коелу турында); 4. *перен. простореч. фам.* к. сыпать 4; 5. *страд.* салыну, тутырылу.

**СЫПНО'Й: сыпной тиф** — тимгелле тиф.

**СЫПНОТИФО'ЗНЫЙ** *мед.* — тимгелле тиф белән авырый торган, тимгелле тиф белән авыручы.

**СЫПНУ'ТЬ** *однокр. разг. фам.* — салып җибәрү, чәчеп җибәрү, сибеп җибәрү.

**СЫПНЯ'К** *м. мн.* нет, *разг.* — тимгелле тиф.

**СЫПУ'ХА** *ж. мн.* нет, *обл.* — 1. к. сыпь 4; 2. тимгелле авыру.

**СЫПУ'ЧЕСТЬ** *ж. мн.* нет — таралучан булу, сибелүчән булу, чәчелүчән булу.

**СЫПУ'ЧИЙ** — 1. сибелүчән, чәчелүчән; бөртекле; *меры сыпучих тел* — бөртекле әйберләр үлчәве; 2. таралучан, таралып тора торган.

**СЫПЬ** *ж.* — 1. *только ед. спец.* (*действие*) к. сыпать 1; 2. *только ед. спец.* (берәр нәрсәгә салына торган) бөртекле әйбернең күләме; 3. *только ед. спец. (сыпучее вещество)* бөртекле әйбер; 4. *(мелкие пятна* или *прыщики)* тимгел; 5. *спец.* кытыршылык; *сыпь на металле* — металлдагы кытыршылыклар; 6 *только ед. (кожа с шероховатой поверхностью)* кытыршы күн; 7. *только ед., собир. тип.* чәчелгән хәрефләр, буталган хәрефләр.

**СЫР** *м.* — сыр (ашамлык). ◇ **Как сыр в масле** (катается) — майда йөзә, май эчендә йөзә, пычагы май эчендә йөзә.

**СЫРЕ'ЙЩИК** *м. охот. старин.* — эткә азык хәзерләүче (үлгән хайван итеннән этләргә ашамлык әзерләүче).

**СЫРЕ'ТЬ** *несов.* — дымлану, дымлана төшү.

**СЫРЕ'Ц** *м. мн.* нет — чимал, эшкәртелмәгән нәрсә.

**СЫ'РНИК** *м.* — 1. сырник (эремчеккә тәмләткеч катнаштырып ясалган ашамлык); 2. эремчек пәрәмәче.

**СЫ'РНЫЙ** — сыр ...-ы; *сырный завод* — сыр заводы. ◇ **Сырная неделя** *устар.* — к. масленица 1.

**СЫРОВА'Р** *м.* — сыр кайнатучы, сыр ясаучы.

**СЫРОВАРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — сыр кайнату, сыр ясау.

**СЫРОВА'РНЫЙ** — сыр кайната торган, сыр ясый торган.

**СЫРОВА'РНЯ** *ж.* — сыр кайната торган предприятие, сыр ясый торган предприятие.

**СЫРОВА'ТОСТЬ** *ж мн.* нет — 1. бераз дымлылык, бераз дымлы булу; 2. пешеп җитмәгәнлек, кыздырылып җитмәгәнлек,

чиле-пешле булу; 3. пешеп житмәгәнлек, өлгереп җитмәгәнлек.

**СЫРОВА'ТЫЙ** — 1. *(несколько сырой)* аз гына дымлы, дымлырак, бераз дымлы; 2. пешеп җитмәгән; ***сыроватые сливы*** — өлгереп җитмәгән, пешеп җитмәгән сливалар; 3. чиле-пешле, пешеп җитмәгән, кыздырылып җитмәгән; ***сыроватое мясо*** — пешеп җитмәгән ит.

**СЫРОДЕ'Л** *м.* — к. сыровар.

**СЫРОДЕ'ЛИЕ** *ср. мн.* нет — к. сыроварение.

**СЫРОДУ'ТНЫЙ** *тех.* — турыдан-туры рудадан алынган; *сыродутное железо* — турыдан-туры рудадан алынган тимер.

**СЫРОЕ'ЖКА** *ж.* — ал гөмбә.

**СЫРО'Й** — 1. юеш, дымлы; *сырые доски* — юеш такталар; *сырой воздух* — дымлы һава; 2. чи, пешерелмәгән, кыздырылмаган; *сырое мясо* — чи ит; 3. чиле-пешле, пешеп җитмәгән; кыздырып җиткерелмәгән; *сырой хлеб* — чиле-пешле икмәк; 4. пешеп җитмәгән, өлгереп җитмәгән, яшел; *сырые яблоки* — яшел алма; 5. чи, эшләнеп бетмәгән; эшләнеп җитмәгән, җитлекмәгән; *сырое произведение* — чи әсәр, эшләнеп бетмәгән әсәр; 6. *перен. разг.* хәлсез симез; *сырой человек* — хәлсез симез кеше. ◇ **Откуда сыр бор загорелся** — к. бор. **Сырая вода** — кайнамаган су.

**СЫРО'К** *м.* — 1. *разг.* к. сыр; 2. сырок (тәмләткечләр катнаштырылган эремчек).

**СЫРОМО'ЛКА** *ж. мн.* нет, *обл.* — чиләтә сугылган ашлыктан тарттырылган он, басуда гына киптереп сугылган ашлыктан тарттырылган он.

**СЫРОМОЛО'Т** *м.*, **СЫРОМОЛО'ТКА** *ж. мн.* нет, *обл. с.-х.* — басуда гына киптереп сугылган ашлык, чиләтә сугылган ашлык.

**СЫРОМЯ'ТИНА** *ж. простореч.* — 1. *только ед., собир.* чи каеш; 2. чи каеш кисәге.

**СЫРОМЯ'ТЬ** *ж. мн.* нет, *собир. спец.* — чи каеш.

**СЫРОПУ'СТ** *м. мн.* нет, *церк.* — масленицаның азакка көне (якшәмбе көн).

**СЫ'РОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. юешлек, дымлылык; *сырость климата* — климатның дымлылыгы; 2. дымлы һава; 3. дым; *от сырости появляется плесень* — дымнан әйберләр күгәрә.

**СЫРТ** *м. обл.* — сырт (тау сырты).

**СЫРЦА'** *ж. мн.* нет, *простореч. фам.* — аз гына дымлылык.

**СЫРЦО'ВЫЙ** — эшкәртелмәгән, чимал ...; *сырцовый шёлк* — эшкәртелмәгән ефәк.

**СЫРЬ** *ж. мн.* нет, *простореч.* — 1. *обл.* к. сырость 2; 2. к. сыроватость.

**СЫРЬЁ** *ср. мн.* нет — 1. чимал; *кожа является сырьём для обувной промышленности* — күн — аяк киеме промышленносте өчен чимал ул; 2. *разг.* чи продукт, пешерелмәгән азык; *ест одно сырьё* — гел пешерелмәгән азык ашый.

**СЫРЬЁМ** *в знач. нареч.* — чи көе, чи килеш, чиләтә, пешермичә.

**СЫРЬЕВО'Й** — чимал ...-ы; *сырьевая база* — чимал базасы.

**СЫСК** *м. мн.* нет, *устар.* — сыск (революциягә кадәрге Россиядә — җинаятьчеләрне эзләү).

**СЫСКА'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* табу, эзләп табу; 2. *истор.* к. разыскать; 3. *офиц. устар.* дәгъвалашып алу.

**СЫСКА'ТЬСЯ** *сов. разг.* — табылу.

**СЫ'СКИВАТЬ** *несов. истор.* — к. сыскать 2.

**СЫСКНО'Й** *устар.*: **сыскная полиция** — сыск полициясе, эзләү полициясе.

**СЫ'ССТАРИ** *нареч. простореч.* — к. исстари.

**СЫТА'** *ж. мн.* нет, *обл.* — ширбәт, баллы су, бал ширбәте.

**СЫТЕ'ТЬ** *несов. простореч.* — 1. тую, ашап тую; 2. *шутл.* ашап симерү.

**СЫТЁХОНЬКИЙ** *простореч.* — бик тук.

**СЫТИ'ТЬ** *несов. обл.* — баллыландыру; ширбәтләндерү.

**СЫТИ'ТЬСЯ** *несов. страд. обл.* — баллыландырылу; ширбәтләндерелү.

**СЫ'ТНО** *нареч.* — туйганчы, ныгытып.

**СЫ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — туклыклылык.

**СЫ'ТНЫЙ** — 1. туклыклы; *сытная пища* — туклыклы ашамлык; 2. *перен. разг. шутл. устар.* төшемле, күп файда китерә торган; *сытное место* — төшемле урын.

**СЫ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — тук булу; туклык.

**СЫ'ТЫЙ** — 1. тук; *сытый голодного не разумеет* — ач кадерен тук белми; 2. көр, симез; *сытый скот* — көр терлек.

**СЫЧ** *м.* — 1. чырайсыз ябалак (кош); 2. *перен. разг.* күңелсез кеше, караңгы чырайлы кеше, чытык кеше.

**СЫЧО'НОК** *м. (мн.* сычáта) — чырайсыз ябалак баласы.

**СЫЧУ'Г** *м.* — 1. төп ашказаны (күшәүче хайваннарда); 2. сычуг (суелган хайванның ашказанына тураган ит тутырып әзерләнгән ашамлык).

**СЫЧУ'ЖИНА** *ж. мн.* нет — сычужина (сөт белән генә туена торган күшәүче хайванның төп ашказанында була торган катлаулы органик матдә, фермент; сыр ясау эшенә китә).

**СЫЧУ'ЖНЫЙ** — сычужина ...-ы; *сычужный фермент* — сычужина ферменты.

**СЫ'ЩИК** *м. доревол.* — шымчы, сыщик, яшерен полиция агенты.

**СЫ'ЩИЦКИЙ** — 1. шымчы ...-ы, шымчылар ...-ы, шымчыларга хас; 2. *простореч.* детектив, шымчылар турындагы; *сыщицкий роман* — детектив роман.

**СЭКОНО'МИТЬ** *сов.* — к. экономить.

**СЭР** *м.* — сэр (1. Англиядә һәм АКШта ир кешегә мөрәҗәгать иткәндә әфәнде мәгънәсендә кулланыла торган сүз; 2. *только ед.* Англиядә ир кешенең исеменә кушып әйтелә торган баронет титулы).

**СЮДА'** *нареч.* — монда, бире, бирегә. ◇ **Ни туда, ни сюда** — к. туда. **Туда и сюда** или **туда, сюда** — к. туда-сюда.

**СЮЖЕ'Т** *м.* — сюжет (1. *лит.* әдәби әсәрнең төп эчтәлеген ачып бирә торган вакыйгалар, хәрәкәтләр барлыгы бергә,

2. *перен. разг.* берәр нәрсәнең темасы, эчтәлеге).

**СЮЖЕ'ТНЫЙ** *лит.* — сюжет ...-ы; *сюжетные элементы* — сюжет элементлары.

**СЮЗЕРЕ'Н** *м. истор.* — сюзерен (феодализм чорында — эре җир биләүче).

**СЮЗЕРЕНИТЕ'Т** *м. мн.* нет, *истор.* — сюзеренлык, сюзеренлык хокукы.

**СЮЗЕРЕ'ННЫЙ** *истор.* — сюзеренлык ...-ы; *сюзеренное право* — сюзеренлык хокукы.

**СЮИ'ТА** *ж. муз.* — сюита (бер идеягә буйсындырылган берничә пьесадан торган музыкаль әсәр).

**СЮРПРИ'З** *м.* — сюрприз (көтелмәгән хәл, бүләк).

**СЮРПРИ'ЗНЫЙ** — сюрприз ..., сюрприз ...-ы; *сюрпризные духи* — сюрприз иселмай.

**СЮРТУ'К** *м.* — сюртук (ирләр киеме).

**СЮРТУ'ЧНИК** *м.* — сюртуклар тегүче.

**СЮРТУ'ЧНЫЙ** — сюртуклык ..., сюртук ...-ы, сюртук тегелә торган; *сюртучное сукно* — сюртук тегелә торган сукно.

**СЮСЮ'КАТЬ** *несов. разг.* — сысылдап сөйләү, сакауланып сөйләү *(ж, ч, ш* урынына *с* чыгарып сөйләү).

**СЯГ** *м. зоол.* — к. сяжок 2.

**СЯЖО'К** *м.* — 1. *обл.* кул җитәрлек ара; 2. *зоол.* мыек (бөҗәкләрдә).

**СЯК** *нареч.*: (и) **так и сяк** — к. так.

**СЯ'КНУТЬ** *несов. устар.* — бетү, кору, кибү.

**СЯКО'Й: такой-сякой** — к. такой-сякой.

**СЯМ** *нареч.*: **там и сям** — к. там.

# Т

**ТА** — к. тот.

**ТАБА'К** *м. мн.* нет, *спец.* — тәмәке; *нюхательный табак* — борын тәмәкесе, насбай. ◇ **Дело табак** — эш начар, эш харап.

**ТАБАКЕ'РКА** *ж. простореч. устар.* — тәмәке савыты (тартмасы), табакерка.

**ТАБАКОВО'Д** *м.* — тәмәке үстерүче, тәмәке үстерү белгече, тәмәке игүче.

**ТАБАКОВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет — тәмәке үстерүчелек, тәмәке үстерү, тәмәке игү.

**ТАБАКОВО'ДЧЕСКИЙ** — тәмәке үстерү...-ы, тәмәке игү...-ы; *табаководческий совхоз* — тәмәке үстерү совхозы.

**ТАБАКУ'Р** *м.* — тәмәке тартучы, тәмәкече, тәмәҗник.

**ТАБА'НИТЬ** *несов. спорт. мор.* — (көймәдә) кирегә ишү.

**ТАБА'НКА** *ж. мн.* нет, *спорт. мор.* — к. табанить.

**ТАБАРГА'Н** *м.* — к. тарбаган.

**ТАБАЧИ'ЩЕ** *м. мн.* нет, *простореч.* — к. табак.

**ТАБА'ЧНИК** *м.* — 1. тәмәке тартучы, тәмәкече, тәмәҗник; борын тәмәкесе (насбай) иснәүче; 2. тәмәкече (тәмәке промышленносте эшчесе, тәмәке промышленностенда эшләүче кеше).

**ТАБА'ЧНИЦА** *ж.* — 1. *простореч.* к. табачник 1; 2. к. табачник 2; 3. *разг.* к. табакерка.

**ТАБА'ЧНЫЙ** — 1. тәмәке...-ы; *табачная фабрика* — тәмәке фабрикасы; 2. *(цвет)* коңгырт сары (төстәге), тәмәке төсендәге; 3. *обл.* черегән; *табачное дерево* — черегән агач.

**ТА'БЕЛЬ** *м.* — табель (1. билгеле бер тәртиптә төзелгән исемлек яки расписание; 2. эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең эшкә килүен һәм эштән китүен хисапка алу өчен эленеп куелган махсус такта яки дәфтәр; 3. *разг. (жетон)* эшкә килгәндә элеп куела торган һәм эштән киткәндә алып куела торган номер). ◇ **Табель о рангах** *истор.* — ранглар табеле (Пётр I заманында төрле чиннарның дәрәҗәсен билгеләү системасы).

**ТА'БЕЛЬНЫЙ** — табель...-ы; *табельная система* — табель системасы. ◇ **Табельный день** *устар.* — бәйрәм көн (якшәмбедән башка бәйрәм көннәре).

**ТА'БЕЛЬЩИК** *м.*, **ТА'БЕЛЬЩИЦА** *ж.* — табельче, табельщик (предприятие һәм учреждениеләрдә эшче һәм хезмәткәрләрнең эшкә килү-китүләрен барлаучы кеше).

**ТА'БЕС** *м. мн.* нет, *мед.* — табес (арка җилеге кибү авыруы, прогрессив паралич).

**ТАБЛАТУ'РА** *ж. мн.* нет — к. табулатура.

**ТАБЛЕ'Т** *м. устар.* — к. таблетка.

**ТАБЛЕ'ТКА** *ж.* — таблетка (кечкенә түгәрәк рәвешендә хәзерләнгән дару).

**ТАБЛИ'ЦА** *ж.* — таблица җәдвәл (берәр нәрсәнең яки берәр нәрсә турындагы мәгълүматларның билгеле бер тәртиптә төзелгән исемлеге); *таблица умножения* — тапкырлау таблицасы.

**ТАБЛИ'ЧНЫЙ** — таблицадагы, таблица...-ы; *табличные сведения* — таблица мәгълүматлары.

**ТАБЛЬДО'Т** *м. спец.* — табльдот (ресторанпарда, курорт ашханәләрендә бар кешегә дә бертөрле хәзерләнгән ашлар бирелә торган өстәл).

**ТА'БОР** *м.* — табор (1. *устар.* элекке казакларда: обоз белән лагерь булып урнашкан гаскәр; 2. бергә күчеп йөрүче чегән семьяларының төркеме һәм вакытлыча урнашкан урыны).

**ТАБОРИ'ТЫ** *м. истор.* — таборитлар (гуситлар хәрәкәтенең сул демократик канаты. Чехиядә Табор дигән авыл исеменнән алынган).

**ТА'БОРНЫЙ** — табор...-ы, чегән...-ы; *таборные песни* — табор җырлары (чегән җырлары).

**ТАБУ'** *ср. нескл.* — табу (борынгы халыкларда дин тарафыннан тыелган эш, әйбер, әйтергә ярамаган сүз).

**ТАБУЛАТУ'РА** *ж. мн.* нет, *муз. истор.* — табулатура (1. ноталар язу өчен кулланыла

торган билгеләр, хәрефләр, цифрлар системасы; 2. тынлы музыка коралында берәр әсәрне башкарганда аның кайсы бакасын, тишеген ачарга яки ябарга кирәклеген күрсәтә торган система).

**ТАБУЛЯ'ТОР** *м. спец.*— табулятор (1. санау машинасы; 2. язу машинкасында таблицалар басу өчен ясалган җайланма).

**ТАБУ'Н** *м.* — көтү, өер (ат, болан һ. б. хайваннарның көтүе, өере).

**ТАБУНИ'ТЬСЯ** *несов. спец.*— көтүгә җыелу, өергә җыелу.

**ТАБУ'ННЫЙ** — көтү...-ы; өер. -ы; *табунный жеребец* — көтү айгыры, өер айгыры.

**ТАБУ'НЩИК** *м.*— көтүче, ат көтүче.

**ТАБУРЕ'Т** *м.* и **ТАБУРЕ'ТКА** *ж.*— табуретка, табурет, артсыз урындык.

**ТАБУРЕ'ТНЫЙ** — табурет...-ы; артсыз урындык...-ы; *табуретная подушка* — табурет мендәре.

**ТАВЕ'РНА** *ж.*— таверна, кечкенә трактир, кечкенә ашханә (Италиядә һ. б. кайбер илләрдә).

**ТАВЛЕЯ'** *ж. старин.*— тавлея (1. шашка уйный торган такта; 2. сөяк шакмак, уен шакмагы).

**ТАВЛИ'НКА** *ж. устар. обл.*— тавлинка (туздан ясалган тәмәке савыты).

**ТА'ВОЛГА** *ж. бот.*— тубылгы (үсемлек).

**ТАВО'Т** *м. тех.*— тавот (машина маеның бер төре).

**ТАВО'ТНИК** *м. тех.*— маслёнка, тавот савыты.

**ТАВО'ТНИЦА** *ж. тех.*— тавотница (механизмнарда: тавот кертеп тору өчен эшләнгән җайланма).

**ТАВРЁНЫЙ** — тамгалы, тамгаланган, тамга сугылган, тамга салынган.

**ТАВРИ'ТЬ** *несов. спец.*— (яндырып) тамга салу, тамгалау.

**ТАВРИ'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— тамга салыну, тамгалану.

**ТАВРО'** *ср.*— тамга (көйдереп салынган тамга).

**ТАВРО'ВЫЙ** *спец.*— тамга...-ы, тамгалы; *тавровый знак* — тамга билгесе.

**ТАВТОГРА'ММА** *ж. лит.*— тавтограмма (һәрбер юлы бер үк хәрефтән башланып китә торган шигырь).

**ТАВТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — тавтологик; *тавтологическое определение* — тавтологик билгеләмә.

**ТАВТОЛО'ГИЯ** *ж. лит.*— тавтология (бер төшенчәне шул төшенчә мәгънәсендәге икенче сүзләр белән кабатлау).

**ТАГА'Н** *м.* — таган, өчаяк.

**ТАДЖИ'КИ** *мн.*— таҗиклар (Таҗикстан ССРның төп халкы).

**ТАДЖИ'КСКИЙ** — таҗик...-ы, таҗиклар...-ы; *таджикский язык* — таҗик теле.

**ТАДЖИ'ЧКА** *ж.*— таҗик хатын-кызы.

**ТАЁЖНИК** *м.*— тайга кешесе, тайгада яшәүче (җәнлекләр аулаучы, алтын эзләүчеләр турында).

**ТАЁЖНЫЙ** — тайга...-ы, тайгадагы, тайгалы; *таёжный охотник* — тайга аучысы.

**ТАЗ** I *м.*— таз, ләгән.

**ТАЗ** II *м. анат.* — оча сөяге (кешедә); янбаш сөяге (хайваннарда).

**ТА'ИВАТЬ** I *многокр. разг.*— яшергәләү, яшерештергәләү.

**ТА'ИВАТЬ** II *многокр. разг.*— эрештергәләү.

**ТАИ'НСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — серлелек, яшеренлек.

**ТАИ'НСТВЕННЫЙ** — 1. серле, яшертен; *таинственный шопот* — серле пышылдау; 2. астыртын; *послать с таинственными целями* — астыртын максатлар белән җибәрү.

**ТА'ИНСТВО** *ср.*—1. к. *устар.* тайна 1, 2; 2. *церк.* серле йола (чукындыру һәм башка төрле йолалар).

**ТАИ'ТЬ** *несов.*— яшерү, сер итеп тоту, яшереп тоту, саклау; *таить злобу* — ачу саклау; *таить своё горе* — үзенең кайгысын яшерү. ◇ **Таить в себе**—...-ы булу; *любое дело может таить в себе трудности* — һәрбер эшнең авырлыклары булуы мөмкин. **Нечего греха таить** *разг.*— дөресен әйтергә кирәк, яшерми әйтергә кирәк.

**ТАИ'ТЬСЯ** *несов.*—1. *разг.* качып яту, качып яшәү, яшеренү, яшеренеп яту; *там всякие звери таились* — анда төрле җәнлекләр яшеренеп ята иде; 2. *разг.* яшерү; *говорить, не таясь* — яшермичә сөйләү; 3. эчендә саклану, саклану, булу, яту; *в этом таится какая то загадка* — монда әллә нинди бер яшерен сер бар.

**ТАЙГА'** *ж. мн.* нет — тайга (Европа һәм Азиянең төньягында куе, күбесенчә ылыслы, кыргый урманнар).

**ТАЙКО'М** *нареч.*— яшереп, яшерен, яшертен, яшерен рәвештә, сиздермичә, белдермичә, астыртын, шыпырт кына; *сделать что-либо тайком* — берәр нәрсәне яшертен эшләү.

**ТАЙМ** *м. спорт.*— тайм (уенның бер өлеше, мәсәлән, футбол уенында билгеләнгән вакытның яртысы — 45 мин.).

**ТАЙМЕ'НЬ** *м.*— Байкал чуртаны, таймень (балык).

**ТАЙМУ'Н** *м. обл.*— таймун, каек (агачтан чокып ясаган кечкенә көймә).

**ТА'ЙНА** *ж.*—1. сер, мәгълүм булмаган нәрсә; *наука проникает во все тайны природы* — фән табигатьнең барлык серләрен ача; 2. сер, яшереп тотылган нәрсә; *государственная тайна* — дәүләт сере. ◇ **Не тайна, что...** — һәркемгә мәгълүм ки...

**ТАЙНИ'К** *м.*—1. яшерен урын, яшерен җир, башкалар белмәгән җир; 2. *обл. охот.* тозак. ◇ **В тайниках души** — күңел үзәгендә, күңел түрендә, йөрәкнең яшерен җирләрендә.

**ТАЙНОБРА'ЧИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *бот. устар.* яшерен аталану, урынтын үрчү (үсемлекләр); 2. *истор.* яшерен никах укыту, яшерен никах уку (никахланырга ярамаган кешеләрне ришвәт алып никах уку).

**ТАЙНОБРА'ЧНЫЙ** *бот. устар.* — яшерен аталана торган; *тайнобрачные растения* — яшерен аталана торган үсемлекләр.

**ТАЙНОПИ'СНЫЙ** *филол.* — к. криптографический.

**ТА'ЙНОПИСЬ** *ж. мн.* нет, *филол.* — к. криптография.

**ТА'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *обл.* — к. тайна. ◇ **По тайности или в тайности** *простореч.* — сер итеп, яшерен рәвештә.

**ТА'ЙНЫЙ** — яшерен, серле, астыртын; *тайный договор* — яшерен договор; *тайная мысль* — яшерен фикер. ◇ **Тайное голосование** — яшерен тавыш бирү. **Тайные выборы** — яшерен тавыш бирү юлы белән үткәрелә торган сайлаулар.

**ТАЙФУ'Н** *м.* — тайфун, диңгез өермәсе (диңгездә була торган көчле давыл).

**ТАК** — 1. *нареч.* шулай, алай; *именно так* — нәкъ шулай; 2. шулкадәр, шулхәтле; *он так быстро говорил, что я ничего не понял* — ул шулкадәр тиз сөйләде, мин бернәрсә дә аңламадым; 3. *нареч. разг.* шулай гына, шул көе, болай гына; *это так не пройдёт* — бу шулай гына үтеп китмәс; 4. болай гына (бернәрсә дә булмады); *что с тобой? — так!* — сина ни булды? — болай гына! 5. икән, булгач; *ехать так ехать* — барырга булгач барырга; 6. *союз* димәк; *так ты мне не веришь?* — димәк, син миңа ышанмыйсың? *так ты согласен?* — димәк, син риза? 7. *усилительная частица разг.* болай, алай; *она так вовсе не изменилась* — ул болай бер дә үзгәрмәгән; 8. *частица* мәсәлән; *климат там суровый, так морозы доходят до 40 градусов* — анда климат бик каты, мәсәлән, салкыннар 40 градуска җитә. ◇ **Всё так** — һаман шул көе. **Давно бы так** *разг.* — күптән, әллә кайчан шулай кирәк иде. **И так** *разг.* — болай да; *и так он нам уже надоел* — ул болай да безне йөдәтеп бетерде инде. **За так получить** *простореч.* — бушлай алу, бушка алу. **И так далее** — һәм башкалар. **И так и иначе или и так и так или так и этак** — алай да, болай да; тегеләй дә, болай да. **Как бы не так** — булмый торсын әле; шулай булмыйни. **Как же так? или как так?** — ничек инде алай? **Не так ли?** — шулай түгелмени? шулай түгелме? **Просто так** — болай гына. **Пусть так** — шулай булсын. **Так бы** *разг.* — тотар идем дә; *так бы уехал* — тотар идем дә китәр идем. **Так и знал** — шулай булыр дип уйлаган идем, алдан белеп тордым. **Слёзы так и льются** — күз яшьләре ага да ага. **Так и быть** — шулай булсын. **Так и есть** — чынлап та шулай булып чыкты, әйткәнемчә булып чыкты. **Так и знай(те)** — белеп тор. **Так или иначе** — һәрхәлдә; тегеләйме, болаймы. **Так и надо** — шулай кирәк тә. **Так и сяк** — алай да, болай да. **Так и так мол** — шулай-шулай дип әйт; шулай-шулай диген, менә шундый-шундый хәлләр диген. **Так как** *союз* — чөнки,...-лыктан,...-га күрә; *нужно было остановить лошадь, так как наша прямая дорога обрывалась* (Чехов) — безнең туры юл өзелгәнгә күрә, атны туктатырга кирәк иде. **Так называемый** — ... дип аталган, дип йөртелә торган. **Так себе** — уртача, бер көе, бертөсле. **Так нет** — юк, тыңламады бит; *сидеть бы ему дома, так нет, пошёл гулять* — өйдә генә утырырга кирәк иде аңа, юк, тыңламады бит, йөрергә чыгып китте. **Так сказать** *ввод. слово* — әйтик ди, әйттек ди. **Так только** *разг.* — болай гына. **Так что** — шуңа күрә, шулай... булгач, шуңлыктан. **Так чтобы** — өчен; *выехать раньше, так чтобы не опоздать на поезд* — поездга соңга калмас өчен, юлга иртәрәк чыгарга кирәк.

**ТА'КАТЬ** I *несов. простореч.* — әйе-әйе дип тору, шулай-шулай дип тору.

**ТА'КАТЬ** II *несов. разг.* — так-так итү, такылдау; *такают пулемёты* — пулемётлар такылдый.

**ТАКЕЛА'Ж** *м. мн.* нет, *мор.* — такелаж (судноның пәжедән һәм металлдан ясалган барлык трослары).

**ТАКЕЛА'ЖИТЬ** *несов. мор.* — такелажлау (судноны трослар белән җиһазлау).

**ТАКЕЛА'ЖНЫЙ** — такелаж...-ы; *такелажные принадлежности* — такелаж кирәк-яраклары.

**ТА'КЖЕ** *нареч.* — 1. шулай ук, да, шуның белән бергә; *мы также согласны* — без шулай ук риза; 2. *присоединит. союз* шулай ук, һәм; *отец, а также мать, ушли* — әти, һәм шулай ук әни, киттеләр.

**ТАКИ** *частица* — 1. шулай да, шулай булса да, барыбер, тәки, шуңа карамастан; *успел-таки на поезд* — шулай да поездга өлгерде. ◇ **Всё-таки** — һәрхәлдә, шулай да. **Опять-таки** — янә, тагын да. **Так-таки** — шулай итеп; *ты так-таки и приехал* — син шулай итеп килдең дәмени инде.

**ТА'КО** *нареч. церк.-книж., устар.* — к. так.

**ТАКО'В** *в знач. сказуемого* — (менә) шундый, (менә) шулай; *таково наше мнение* — безнең фикер менә шулай. ◇ **И был таков** *разг.* — тайды, шылды, күздән югалды. **Каков поп, таков и приход** — мулласына күрә мәчете; чиләгенә күрә капкачы.

**ТАКОВО'Й** *устар. канц.* — ул, шул, шундый, мондый, андый; *в случае утери документа, таковой вновь не выдаётся* — документны югалткан очракта, ул яңадан бирелми. ◇ **Как таковой** *книж. канц.* — үзеннән-үзе, үзеннән-үзе алынганда; *вопрос важен как таковой* — мәсьәлә үзеннән-үзе мөһим.

**ТАКО'ВСКИЙ** *разг. фам. пренебр.* — к. такой 1.

**ТАКО'Й** — 1. андый, шундый, мондый; *такой товар нам не нужен* — андый товар безгә кирәкми; *такой красивый* — шундый матур; 2. *разг.* шундый, әллә нинди; *лень такая напала* — әллә нинди ялкаулык басты; 3. *в знач. сущ.* шундый, шундый нәрсә; *такое говорят, что слушать даже неприятно* — шундый нәрсә сөйлиләр, хәтта тыңларга да күңелсез.

◇ **В таком положении** *разг. эвф.* — корсаклы, йөкле (хатыннар турында). **В таком случае и в таком разе** — алай булгач, болай булгач; *в таком случае я еду немедленно* — алай булгач, мин хәзер үк китәм. **До такой степени** — шулкадәр, бу кадәр. **Таким образом** — димәк, шул рәвешчә, шулай итеп. **Есть такое дело** — ярый, эшләрмен; син дигәнчә булыр; булды. **И всё такое** — һәм башкалар. **Какой-такой?** — нинди? **Кто такой?** — кем ул? **Такой же** — шундый ук. **Такой же ... как** — бер үк, шикелле, шуның кебек, нәкъ шуның төсле, шул ук. **Что ж тут такого** *разг.* — нәрсә (ни) булган соң? бер дә искитәрлек нәрсә юк. **Что (же это) такое** — бу нәрсә инде, бу нинди эш инде, бу нинди хәл инде.

**ТАКО'Й-СЯКО'Й** *разг. фам.* — фәлән-фәсмәтән; *ах, он такой-сякой* — ах, ул фәлән-фәсмәтән.

**ТАКО'Й-ТО** — фәлән кеше, шул кеше (билгеле булмаган яки исеме әйтелмәгән кешенең исемен алмаштыра).

**ТАК-С** и **ТЭК-С** *частица* — әйе, шулай.

**ТА'КСА** I *ж.* — такса (рәсми рәвештә билгеләнгән бәя).

**ТА'КСА** II *ж.* — такса (эт токымы).

**ТАКСА'ТОР** *м. спец.* — таксатор (1. такса куючы, бәя билгеләүче, хак куючы; 2. урмандагы агачларның күләмен билгеләүче; уңышның күләмен билгеләүче).

**ТАКСА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — таксация (1. бәяләү, бәя куеп чыгу, хак кую; 2. урмандагы агачларның күләмен билгеләү; 3. *с.-х.* уңышның күләмен билгеләү).

**ТАКСИ'** *ср. нескл.* — такси (акча алып кешеләр йөртә торган һәм йөртү бәясен күрсәтеп тору өчен махсус счётчик куелган автомобиль); *грузовое такси* — йөк таксие.

**ТАКСИ'МЕТР** *м. спец.* — таксиметр (автомобильнең күпме юл йөргәнлеген күрсәтә торган счётчик).

**ТАКСИМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет — таксиметрия (хәрәкәтнең тизлеген билгеләү).

**ТАКСИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — такса кую, такса билгеләү, бәя кую.

**ТАКСИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — такса куелу, такса билгеләнү, бәя куелу.

**ТАКСИ'СТ** *м. простореч.* — такси шофёры, таксист.

**ТАКСО'МЕТР** *м. спец.* — таксометр (автомобильнең күпме юл йөргәнен һәм автомобильдән файдаланган өчен күпме акча түләргә кирәклеген күрсәтеп тора торган махсус счётчик).

**ТАКСОМОТО'Р** *м.* — к. такси.

**ТАКСОФО'Н** *м.* — автомат телефон.

**ТАК-СЯ'К** *в знач. сказ. простореч.* — бер хәл; *ну это ещё так-сяк* — анысы әле бер хәл.

**ТАКТ** I *м.* — такт (1. *муз.* музыкада метрик берәмлек; 2. нинди дә булса бертигез хәрәкәтнең һәрбер өлеше, мәсәлән, йөрәк тибү тактлары).

**ТАКТ** II *м.* — такт, әдәп, тотнаклылык; *держать себя с тактом* — үзеңне әдәпле тоту.

**ТА'К-ТАКИ** *частица разг.* — шуңа карамастан, шулай да, тәки; *ты сумел так-таки добиться своего* — шулай да син үз теләгеңә ирештең.

**ТА'КТИК** *м.* — тактика белгече, тактик.

**ТА'КТИКА** *ж.* — тактика (1. *воен.* гаскәри частьлар белән сугышны алып бару сәнгате, сугыш вакытында гаскәрләр белән идарә итү сәнгате; 2. *перен.* алга куйган максатка ирешү өчен кулланыла торган барлык методлар); *революционная тактика пролетариата* — пролетариатның революцион тактикасы.

**ТАКТИ'ЛЬНЫЙ** *науч.* — тоеп беленә торган, тоела торган.

**ТАКТИ'ЧЕСКИЙ** *воен.* — тактик, тактика...-ы; *тактические учения* — тактик өйрәнүләр; *тактическое руководство* — тактик житәкчелек.

**ТАКТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тактлылык, тотнаклылык, әдәплелек; *проявлять тактичность* — әдәплелек күрсәтү.

**ТАКТИ'ЧНЫЙ** — тактлы, әдәпле, тотнаклы; *тактичный человек* — тактлы кеше.

**ТА'К-ТО** *разг.* — 1. *нареч.* шулмы, шул да булдымы инде, шул булдымы инде; *так-то ты меня слушаешь* — шул булдымы инде синең мине тыңлавың; 2. *частица* чыннан да, дөрестән дә, чынлап та; *так-то было дело* — чынлап та, эш шулай булган иде. ◇ **Не так-то** *разг.* — бик үк... түгел, ул кадәр... түгел, артык... түгел; *он не так-то стар* — ул бик үк карт түгел. **Так-то и так-то** *разг.* — шулай-шулай; *сделайте, говорит, это так-то и так-то* — моны шулай шулай эшләгез, ди. **Так-то так** *разг. ввод. слово* — алаен алай да; шулаен шулай да; *так-то так, но ты всё-таки неправ* — алаен алай да, ләкин син шулай да хаклы түгел.

**ТА'КТОВЫЙ** — такт...-ы, тактлар...-ы *тактовая черта* — такт сызыгы (нотада)

**ТАЛ** *м. обл.* — тал.

**ТАЛА'Н** *м. нар. поэт. простореч.* — бәхет, язмыш; *всякому свой талан* (А. Кольцов) — һәркемнең үз бәхете.

**ТАЛА'НИТЬ** *несов. нар.-поэт. простореч.* — бәхет булып тору, бәхет килеп тору, мач килеп тору, жае килеп тору.

**ТАЛА'НИТЬСЯ** *несов. нар.-поэт. простореч.* — к. таланить.

**ТАЛА'НЛИВЫЙ** *нар.-поэт. просторечь.* — бәхетле, уңышлы.

**ТАЛА'НТ** *м.* — 1. *только ед.* талант, сәләт; 2. талантлы кеше, талант; *молодые таланты* — яшь талантлар; 3. талант (а. борынгы Грециядә: авырлык үлчәве һәм акча берәмлеге; б. хәзерге Грециядә: авырлык үлчәве берәмлеге — 150 *кг*). ◇ **Зарыть талант в землю** — талантны жиргә күмү, талантны харап итү.

**ТАЛА'НТЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — талантлылык, талантлы булу, талант иясе булу.

**ТАЛА'НТЛИВЫЙ** — талантлы; *талантливый писатель* — талантлы язучы.

**ТА'ЛЕР** I *м.*— талер, көмеш тәңкә, талер тәнкә (немецларның 3 маркага тигез булган борынгы көмеш акчасы).

**ТА'ЛЕР** II *м. тип.*— талер (1. типографиядә басу машинасының набор, стереотип куя торган металл такта; 2. наборны басарга хәзерләгәндә эш итә торган махсус өстәл).

**ТА'ЛИ** *ед.* нет, *тех. мор.*— тали (йөк күтәрә торган чыгырлар системасы).

**ТАЛИ'НА** I *ж. обл.*— к. проталина.

**ТАЛИ'НА** II *ж. обл.*— к. тальник.

**ТАЛИСМА'Н** *м.*— тылсым, бөти.

**ТА'ЛИЯ** I *ж.*—1. бил; *тонкая талия* — нечкә бил; *платье в талию* — билне кысып тора торган күлмәк; 2. бил (күлмәкнең бил өлеше).

**ТА'ЛИЯ** II *ж.*— талия (1. ике колода уен кәрте; 2. колодадагы барлык кәртләрнең уенда бер кат әйләнеп чыгуы).

**ТА'ЛКИВАТЬ** *несов. разг.*— этқәләү, эткәләү-төрткәләү.

**ТА'ЛЛИЙ** *м. мн.* нет — таллий (химик элемент, ак йомшак металл).

**ТАЛМУ'Д** *м.*— талмуд, тәүрат (дингә ышанучы еврейләрнең дин-хокук, көнкүреш мәсьәләләренә караган борынгы дини китабы).

**ТАЛМУДИ'СТ** *м.*—1. талмуд тарафдары, талмуд белгече; 2. *перен пренебр.* талмудчы (эшнең асылына төшенмичә, аңламыйча эш итүче кеше).

**ТАЛМУДИ'СТСКИЙ** и **ТАЛМУДИ'ЧЕСКИЙ** — 1. талмуд...-ы, талмудка нигезләнгән; 2. талмудчыларча..., догматикларча..., талмудчыларга хас (булган); *талмудистское толкование* — талмудчыларча аңлату.

**ТАЛО'Н** *м.*— талон (1. берәр әйбер алу өчен бирелгән язу; 2. берәр документның ертып алына торган өлеше яки ертып алганда кала торган өлеше); *талон чека* — чекның талоны (банкның кассасыннан акча алу өчен чекны банкка тапшырганда ертып бирелә торган кисәге).

**ТА'ЛЫЙ** — 1. эрегән, эреп йомшаган, җепшек; *талый снег* — җепшек кар; 2. эреп йомшаган, җебегән; *талая рыба* — эреп йомшаган балык. ◇ **Талая вода** — кар суы.

**ТАЛЬ** *ж. мн.* нет, *обл.*— җепшек, җепшек көн.

**ТА'ЛЬВЕГ** *м. геогр. геодез.*— тальвег (рельефның уйсу урыны).

**ТАЛЬК** *м. мн.* нет — тальк (техникада һәм медицинада кулланыла торган, порошок рәвешендәге йомшак минерал).

**ТА'ЛЬКА** *ж. обл.*— 1. әвернә; 2. киләп.

**ТА'ЛЬКОВЫЙ** — тальклы, тальк...-ы.

**ТА'ЛЬМА** *ж.*— тальма (хатын-кызларның иңбашына салып йөри торган җиңсез кием).

**ТАЛЬНИ'К** *м.*— тал куагы, таллык.

**ТА'ЛЬЯ** *ж.*— к. талия II.

**ТАЛЬЯ'НКА** *ж. простореч. обл.*— тальян гармонь, тальянка.

**ТАМ** — 1. *нареч.* анда, шунда, тегендә; *я там буду завтра* — мин анда иртәгә булам; 2. *нареч. разг.* аннары, аннан соң, соңыннан; *там видно будет, что делать* — нишләргә икәне күренер аннары. ◇ **Какое там** — кая ул, юк инде, каян килсен ди, каян булсын ди; *только собрался выходить — какое там! опять дождь пошёл* — чыгарга гына җыенган идем — кая ул! тагы яңгыр ява башлады. **Там же** — шунда ук; элекке урынында; *он живёт там же* — ул шунда ук тора (яши). **Там и тут** или **там и сям** — тегендә дә, монда да; анда да, монда да; кая карама шунда. **Чего там!** — әйдә, игътибар итмә; *бери, чего там!* — әйдә, ала бир!

**ТАМАДА'** *м.*— тамада (аш мәҗлесе башлыгы).

**ТАМАРИ'КС** *м. бот.*— к. тамариск.

**ТАМАРИ'НД** *м. бот.*— тамаринд, һинд хөрмәсе (тропик өлкәләрдә үсә торган мәңге яшел агач; җимешләреннән дару ясала).

**ТАМАРИ'СК** *м. бот.*— тамариск (көньякта үсә торган тәңкә яфраклы куаклык).

**ТА'МБУР** *м.*— тамбур (1. *устар.* барабан; 2. *архит.* түбәсе гөмбәзләп ябылган бинаның цилиндр формасындагы яки күп кырлы өлеше; 3. *архит.* ишек алдындагы кечкенә корылма, кечкенә бүлмә; 4. *ж.-д.* пассажир вагонының ике башында да булган өсте ябык мәйданчыгы; 5. *спец.* күпертеп чигелгән чигү; 6. *муз.* кәнчыгышта мандолинасыман кыллы музыка коралы).

**ТАМБУРИ'Н** *м.*— тамбурин (1. кырыйларында шөлдерләре булган, күн киертелгән кыршаудан гыйбарәт бәреп уйнала торган музыка коралы; 2. *устар.* озынча корпуслы зур барабан).

**ТАМБУРМАЖО'Р** *м. воен. устар.*— (полкта) өлкән барабанчы.

**ТАМГА'** *ж.*—1. тамга; 2. *старин.* тамга, келәймә; 3. *истор.* тамга (борынгы Русьта таможняларда товарларга келәймә салганда түләтелә торган пошлина).

**ТАМО'ЖЕННИК** *м.*— таможняда хезмәт итүче, таможня хезмәтчесе.

**ТАМО'ЖНЯ** *ж.*— таможня (чик аша үтә торган товарларны карау, шундый товарлардан налог алу кебек эшләрне башкаручы учреждение).

**ТА'МОШНИЙ** *разг.*— андагы, шундагы, тегендәге, анда..., шунда..., тегендә...; *тамошние жители* — анда яшәүчеләр.

**ТАМПО'Н** *м. мед.*— тампон (эренен бетерү яки канны туктату өчен яраның эченә куела торган мамык яки марля кисәге).

**ТАМПОНА'Ж** *м. мн.* нет, *горн.*— тампонаж (нефть скважинасын яки тау токымы ярыкларын һәм буш урыннарны җир асты суларыннан саклау өчен цемент, кызыл балчык яки битум белән тутыру).

**ТАМПОНА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— к. тампонировать.

**ТАМПОНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. мед.*— тампон кую (җәрәхәткә, ярага).

**ТАМПОНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. мед.*— тампон куелу.

**ТАМ-СЯ'М** *нареч. разг.*— к. там.

**ТАМТА'М** *м. муз.*— тамтам (Кытай, Индонезия кебек илләрдә музыка коралы).

**ТА'НГЕНС** *м. мат.*— тангенс (почмакның тригонометрик функциясе).

**ТА'НГО** *ср. нескл.*— танго (танецның бер төре).

**ТА'НДЕМ** *м. нескл.*— к. тендем.

**ТА'НЕЦ** *м.*—1. танцы, бию; ***народные танцы*** — халык биюләре; **2.** танцы (танцы өчен язылган музыка әсәре, бию көйләре).

**ТАНИ'Н** *м. мн.* нет — танин (имән һәм башка агачларның кайрысыннан эшләп чыгарылган саргылт порошок — медицинада һәм дуплау эшендә кулланыла).

**ТАНК** *м.*— танк; ***тяжёлый танк*** — авыр танк; ***лёгкий танк*** — җиңел танк.

**ТА'НКЕР** *м. мор.* — танкер (сыек, күбесенчә, нефть кебек әйберләрне турыдантуры үзенә төяп ташу өчен ясалган судно); ***танкер для нефти*** — нефть ташый торган танкер.

**ТА'НКЕРНЫЙ** *мор.*— танкер...-ы; танкерлар...-ы; ***танкерный флот*** — танкерлар флоты.

**ТАНКЕ'ТКА** *ж. воен.*— танкетка (тиз йөрешле кечкенә танк).

**ТАНКЕ'ТКИ** *мн.* (*ед.* танкетка *ж.*) — танкетка (хатын-кызларның аяк киеме).

**ТАНКИ'СТ** *м.*— танкист.

**ТАНКОВОЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *воен.*— танк йөртү; ***искусство танковождения*** — танк йөртү осталыгы.

**ТА'НКОВЫЙ** — танк...-ы, танклар...-ы; ***танковые части*** — танк частьлары; ***танковая атака*** — танклар атакасы (танклар белән атака ясау).

**ТАНКОДРО'М** *м. воен.*—танкодром (танкларны сынап карый һәм танк йөртергә өйрәтә торган мәйдан).

**ТАНКОСТРОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — танк төзү, танклар төзү.

**ТАНКОСТРОИ'ТЕЛЬ** *м.* — танклар төзүче, танк эшләп чыгаручы.

**ТАНКОСТРОИ'ТЕЛЬНЫЙ** — танклар төзү...-ы, танк төзү...-ы; ***танкостроительная промышленность*** — танклар төзү промышленносте.

**ТАННИ'Н** *м.*— к. танин.

**ТАНТА'Л** *м. мн.* нет, *хим.*— тантал (бик каты металл).◇ **Танта́ловы му́ки** — тантал газаплары, газап чигү.

**ТАНЦЕВА'ЛЬНЫЙ** — бию...-ы; танцы...-ы; ***танцевальный вечер*** — бию кичәсе, танцы кичәсе.

**ТАНЦЕВА'ТЬ** *несов.*— бию, танцы бию, танцевать итү.

**ТАНЦЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— биелү, танцевать ителү.◇ **Танцевать от печки** — к. печка.

**ТАНЦКЛА'СС** *м. устар.*— танцкласс (танцыга өйрәтү мәктәбе).

**ТАНЦМЕ'ЙСТЕР** *м. устар.*— танцмейстер, танцыга өйрәтүче.

**ТАНЦОВА'ЛЬНЫЙ** — к. танцевальный.

**ТАНЦОВА'ТЬ** *несов.*— к. танцевать.

**ТАНЦОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— к. танцеваться.

**ТАНЦО'ВЩИК** *м.*—1. *устар.* биюче; **2.** балет артисты.

**ТАНЦО'ВЩИЦА** *ж.*—1. биюче; **2.** балет артисткасы.

**ТАНЦО'Р** *м.*, **ТАНЦО'РКА** *ж.*— биюче, бии белүче, танцевать итүче.

**ТАНЦУ'ЛЬКА** *ж. просторен. пренебр.*— танцы кичәсе.

**ТАПЁР** *м.*, **ТАПЁРША** *ж.*— тапёр (танцы кичәләрендә ялланып пианинода уйнаучы музыкант).

**ТАПИ'Р** *м. зоол.*— тапир (ирене һәм борыны хортумсыман сузылган сыңар тояклы имезүче хайван).

**ТА'ПЛИВАТЬ** I *многокр. разг.* — **1.** яккалау, яккалаштыру; **2.** эреткәләү, эреткәләштерү.

**ТА'ПЛИВАТЬ** II *многокр. разг.*— батыргалалу, батыргалаштыру.

**ТА'ПОЧКИ** *ж. разг.*— тапочка (үкчәсез җиңел аяк киеме).

**ТА'ПТЫВАТЬ** *многокр. разг.*— тапташтыру, тапташтыргалау.

**ТА'РА** *ж. мн.* нет — тара (**1.** товар салып, тутырып яки төреп йөртә торган савыт; тартма, капчык, чыпта кебек әйберләр; **2.** *торг.* шул әйберләрнең авырлыгы).

**ТАРАБА'НИТЬ** *несов. разг. фам.* — дөбер-шатыр эшләү, шатыр-шотыр эшләү, дөбер-шатыр бару.

**ТАРАБА'РИТЬ** *несов. просторен.*— ләчтит сату, юк-барны сөйләү, лыкылдау.

**ТАРАБА'РСКИЙ** —**1.** *старин.* к. криптографический; 2. *разг. перен.* аңлаешсыз, мәгънәсез; ***тарабарское выражение*** — аңлаешсыз тәгъбир; ***тарабарская грамота*** — аңлаешсыз бернәрсә.

**ТАРАБА'РЩИНА** *ж. мн.* нет, *устар.* — **1.** к. тарабарский 1; **2.** *перен.* аңлаешсыз нәрсә, мәгънәсез нәрсә.

**ТАРАКА'Н** *м.*— таракан; ***чёрный таракан*** — кара таракан.

**ТАРАКА'ШКА** *разг. фам.*—**1.** *м* к. таракан; 2. *м.* и *ж.* ***(маленькое насекомое)*** кечкенә бөҗәк.

**ТАРА'Н** *м.*— таран (**1.** борынгы сугышларда крепость стеналарын җимерү коралы; **2.** электә сугыш корабльләренең борынында дошман корабльләрен төртеп тишәр өчен ясалган җайланма; **3.** дошман самолётын яки танкысын үз самолёты яки танкысы белән бәреп атакалау; **4.** *перен. воен.* дошман фронтын өзеп керү).

**ТАРА'НИЙ** — Азов чабагы...-ы, тарань балыгы...-ы, Азов чабагыннан пешерелгән; ***таранья уха*** — тарань балыгы шулпасы.

**ТАРА'НИТЬ** —**1.** *несов.* төрттерү, таран белән төрттерү; **2.** *сов.* и *несов.* таранлау (самолёт яки танк белән дошман самолётын яки танкын бәреп төшерү яки вату); **3.** *несов.* бәреп тишү, төрттереп тишү; **4.** *несов.* өзеп керү, тишеп керү.

**ТАРА'НИТЬСЯ** *несов. страд.*— таран белән төрттерелү, таран белән тиштерелү, таранлану.

**ТАРА'ННЫЙ** — таран...-ы, тараннар...-ы; ***таранные цепи***—таран чылбырлары. ◇ **Таранная кость** *анат.*— тубык сөяге.

**ТАРАНТА'** *ж. мн.* нет, *разг. фам.*— такылдык, тел бистәсе.

**ТАРАНТА'С** *м.*— тарантас.

**ТАРАНТЕ'ЛЛА** *ж.*— тарантелла (1. Италиядә халык биюе; 2. шушы бию көе характерындагы музыкаль әсәр).

**ТАРАНТИ'ТЬ** *несов. разг. фам.*— бик тиз сөйләү, такылдау.

**ТАРА'НТУЛ** *м.*— тарантул, бөе (чага торган агулы үрмәкүч).

**ТАРА'НЬ** *ж.*— тарань балыгы, Азов чабагы (Азов һәм Кара диңгезләрдә яши торган балык).

**ТАРАРА'М** *м. мн.* нет, *разг. фам.*— шаушу, гауга, дау; *поднять тарарам* — шаушу куптару.

**ТАРАРА'Х** *в знач. сказ., простореч. фам.*— бик каты сукты, бик каты бәрде.

**ТАРАРА'ХАТЬ** *несов. простореч. фам.*— к. тарарахнуть.

**ТАРАРА'ХНУТЬ** *сов. простореч. фам.*— бик каты итеп (бәрү) сугу; гөрс итеп ату.

**ТАРАТА'ЕЧНЫЙ** — ике тәгәрмәчле арба ...-ы; *таратаечная ось* — ике тәгәрмәчле арба күчәре.

**ТАРАТА'ЙКА** *ж.*— ике тәгәрмәчле арба, җиңел арба.

**ТАРАТО'РА, ТАРАТО'РКА** *м.* и *ж. разг. фам.*— лыкылдык, тел бистәсе.

**ТАРАХТЕ'ТЬ** *несов. разг.*— дыңгырдау, шыгырдау; *вдали тарахтела телега* — еракта арба дыңгырдый иде.

**ТАРА'ЩИТЬ** *несов. разг. фам.*— (күзне) акайту, (күзне) акайтып карау, (күзне) чекрәйтү.

**ТАРА'ЩИТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— акаю, чекрәю.

**ТАРБАГА'Н** *м.*— тарбаган (далаларда яши торган кимерүче хайван).

**ТАРЕ'ЛКА** *ж.*—1. тәлинкә; *мелкая тарелка* — сай тәлинкә; 2. тарелка (бер-берсенә бәреп уйный торган музыка коралы). ◇ **Быть не в своей тарелке** — кәефсез булу, кәеф кырылып тору, ачу килеп тору, күңел төшеп тору.

**ТАРЕ'ЛОЧКА** *ж.*—1. кечкенә тәлинкә; 2. *спец.* кечкенә түгәрәк мишень; *стрельба по тарелочкам* — кечкенә түгәрәк мишеньнәргә ату.

**ТАРЕ'ЛОЧНИК** *м. спец.*— тарелкаларда уйнаучы (оркестрда — музыкант).

**ТАРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— та́ралау (1. тараның авырлыгын билгеләү; 2. тара ярдәмендә әйбернең авырлыгын билгеләү; 3. бер приборның күрсәтүләрен контроль прибор күрсәтүләренә чагыштырып тикшерү).

**ТАРИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— та́ралану.

**ТАРИ'Ф** *м.*— тариф (бәяләр яки түләү хаклары күрсәтелгән рәсми исемлек); *тарифы заработной платы* — эш хакы тарифлары; *почтовый тариф* — почта тарифы.

**ТАРИФИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— тарификацияләү, тарификация ясау, тарифлау, тариф билгеләү; *тарификация заработной платы* — эш хакы тарифларын билгеләү.

**ТАРИФИЦИ'РОВАТЬ** *несов. спец.*— тариф билгеләү, тарификацияләү.

**ТАРИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— тариф билгеләнү, тарификацияләнү.

**ТАРИ'ФНЫЙ** —1. тариф...-ы; тариф буенча билгеләнгән; *тарифная сетка* — тариф челтәре; *тарифные ставки* — тариф буенча билгеләнгән ставкалар (эш хаклары); 2. тарификация...-ы, тарифлау...-ы, тарификацияләү...-ы; тарифлар билгеләү...-ы; *тарифное бюро* — тарифлар билгеләү бюросы.

**ТАРЛАТА'Н** *м. мн.* нет, *устар.*— тарлатан (үтә күренә торган юка тукыма).

**ТАРПА'Н** *м.*— тарпан, кыргый ат.

**ТАРТА'ЛЬЩИК** *м. спец.*— тартальщик, нефть тартучы, тартып чыгаручы (нефтьне махсус чиләк белән чүмереп чыгаручы эшче).

**ТАРТА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *горн.*— тарту, тартып чыгару (нефтьне чиләк белән чүмереп чыгару).

**ТАРТА'Р** *м. мн.* нет — тәмуг, җәһәннәм (греклар мифологиясендә).

**ТАРТАРАРЫ'** *ед.* нет, *нескл.*: **провалиться бы им в тартарары** — җир йоткырлары, җәһәннәмгә киткерләре.

**ТАРТИ'НКА** *ж. устар.*— к. бутерброд.

**ТАРХА'Н** *м.* – тархан (1. *истор.* феодаль Русьта—аерым хокукларга ия булган, салымнардан азат ителгән вотчина хуҗасы; 2. *истор.* шундый хокуклар бирә торган ярлык; 3. *обл. устар.* вак сәүдәгәр).

**ТАРХА'ННЫЙ** *истор.*—1. тархан...-ы; *тарханные права* — тархан хокуклары; 2. *истор.* тархан...-ы, тарханлык...-ы; *тарханная грамота* — тарханлык ярлыгы.

**ТА'СКА** *ж. мн.* нет — к. таскать 1, 2.

**ТАСКА'ТЬ** *несов.*—1. ташу, күтәреп ташу, күтәреп йөртү; *таскать брёвна* — (күтәреп) бүрәнә ташу; *таскать с собой книги* — китапларны үзең белән күтәреп йөртү; *таскать сор* — чүп ташу; 2. тарту, өстерәп йөртү, сөйрәп йөртү; *таскать за волосы* — чәченнән сөйрәп йөртү; *таскать за уши* — колагыннан тарту; 3. *разг. фам.* чыгару, суыру; *таскать гвозди из стены* — стенадан кадаклар суыру; 4. ияртеп йөртү; *таскать кого-н. с собой по магазинам* — берәр кешене үзең белән магазиннарга ияртеп йөртү; 5. йөртү, йөртеп йөдәтү; *таскать по судам* — судларга йөртү; 6. алу; *ястреб таскает кур* — карчыга тавыкларны ала; 7. киеп йөрү, сөйрәү; *третий сезон таскает одно платье* — бер күлмәкне өченче ел сөйри; 8. *спец. (о лошади)* буйлау. ◇ **Он еле ноги таскает** — ул чак-чак аягын сөйри, ул чак-чак кына йөри, ул көчхәл белән генә йөри.

**ТАСКА'ТЬСЯ** *несов.*—1. *разг. фам.* сөйрәлеп йөрү; селкенеп йөрү; бәлтерәп йөрү; *таскается без дела по улицам* — урамда эшсез селкенеп йөри; 2. *простореч. фам. устар.* себерелеп йөрү, сөйрәлү, сөйрәлеп йөрү; *таскаться за красавицами* — чибәр хатын-кызлар артыннан сөйрәлү.

**ТА'СКИВАТЬ** *многокр. разг.*— к. таскать.

**ТАСКОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *простореч. фам.* ташыну; күчену, күчеп йөрү; *таскотня по гостиницам совсем замучила*

*его* — гостиницадан гостиницага күчеп йөрү аны интектереп бетерде инде.

**ТАСКУ'Н** *м. простореч. фам. неодобр.*— өстерәлчек, сөйрәлчек, себерке (хатын-кыз артыннан йөрергә яратучы).

**ТАСКУ'НЬЯ** *ж. простореч. фам. неодобр.*— өстерәлчек, сөйрәлчек, ирләр белән йөрергә яратучы, себерке (ирләр белән чуалып йөри торган хатын-кыз турында әйтелә).

**ТАСОВА'ТЬ** *несов.*—1. аралаштыру, бутау (уен карталарын); 2. *разг. фам. неодобр.* (анда-монда) урнаштыру, төрле урынга урнаштыру.

**ТАСОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*—1. аралаштырылу, буталу (уен карталары); 2. андамонда урнаштырылу, төрле урынга урнаштырылу (кешеләр турында).

**ТАСО'ВКА** *ж. мн.* нет—к. тасовать.

**ТА'ТА** *м. обл.*— к. тятя.

**ТАТА'РКА** I *ж.*— татар хатын-кызы.

**ТАТА'РКА** II *ж. бот.*— көпшә суган.

**ТАТА'РНИК** *м. мн.* нет, *бот.*— шайтан таягы, убырут (үсемлек).

**ТАТА'РСКИЙ** — татар...-ы, татарлар...-ы; Татарстан...-ы; *татарский язык* — татар теле; *Татарский экономический район* — Татарстан экономик районы.

**ТАТАРЧО'НОК** *м. (мн.* татарча́та) — татар малае.

**ТАТА'РЩИНА** *ж. мн.* нет, *старин.*— 1. борынгы Русьның татар-монголлар кул астында булган дәвере; 2. татар-монгол ханнарына түләнгән ясак.

**ТАТА'РЫ** *мн.*— татарлар, татар халкы.

**ТАТЕ'БНЫЙ** *старин.*— караклык...-ы, талау...-ы; юлбасарлык...-ы, бурлык...-ы, *татебные дела* — караклык эшләре.

**ТА'ТКА** *м. обл.*— к. тата.

**ТА'ТСКИЙ** — татлар ...-ы, тат ...-ы; *татский язык* — тат теле.

**ТАТУИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— татуировкалау, (бетми торган буяуга манылган инәләр белән чәнчеп) тәнне бизәкләү, тәнгә рәсем ясау.

**ТАТУИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.*—1. татуировкалану, үз тәненне бизәкләү; үз тәненә рәсемнәр ясау; 2. *страд.* татуировкалану, тәнгә рәсемнәр төшерелү.

**ТА'ТЫ** *мн.*— татлар, тат халкы (Азербайҗанда һәм Дагстанда яшәүче, тел ягыннан иран группасына караган халыкның исеме).

**ТАТЬ** *м. старин.*— карак, юлбасар.

**ТАТЬБА'** *ж. мн.* нет, *старин.*— бурлык, караклык, урлашу, юлбасарлык итү.

**ТА'У-САГЫ'З** *м. мн.* нет — таусагыз (каучук бирә торган үсемлек).

**ТАФТА'** *ж. мн.* нет, *старин.*— тафта (юка тыгыз ефәк тукыма).

**ТАФТЯНО'Й** — тафта...-ы, тафтадан тегелгән.

**ТАФЬЯ'** *ж. старин.*— такыя (түбәтәйнең кәләпүшнең бер төре).

**ТАХЕО'МЕТР** *м. геодез.*— тахеометр (җир үлчәү һәм план төшерү эшендә кулланыла торган прибор).

**ТАХЕОМЕТРИ'ЧЕСКИЙ** — тахеометрия...-ы, тахеометрик; *тахеометрические работы* — тахеометрик эшләр.

**ТАХЕОМЕ'ТРИЯ** *ж. мн.* нет — тахеометрия (җир рельефының планын төзү өчен ерактан җирләрнең топографик рәсемен төшереп алу).

**ТАХИКАРДИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.*— тахикардия (йөрәк тибүенең ешаюы, көчәюе).

**ТАХО'МЕТР** *м. спец.*— тахометр (двигательнең валның һ. б. почмакча тизлеген үлчи торган прибор).

**ТАХТА'** *ж.*— тахта (артсыз диван).

**ТАЧА'ЛКА** *ж. тех.*— тачалка (тимер чыбык белән брошюровкалый торган машина).

**ТАЧА'ЛЬНЫЙ** *сапож. порт.*— каю ...-ы; тегү ...-ы; *тачальная машина* — каю машинасы.

**ТАЧА'ЛЬЩИК** *м.*, **ТАЧА'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*— тегүче, каючы.

**ТАЧА'НКА** *ж.*— тачанка (ике яки дүрт тәгәрмәчле җиңел арба); *пулемётная тачанка* — пулемёт тачанкасы (пулемёт урнаштырылган тачанка).

**ТАЧА'ТЬ** *несов. сапож. порт.*— тегү, каю; *тачать сапоги* — итек тегү.

**ТАЧА'ТЬСЯ** *несов. страд. сапож. порт.*— тегелү, каелу.

**ТА'ЧКА** I *ж. мн.* нет, *сапож. порт.*— к. тачать.

**ТА'ЧКА** II *ж.*— тачка (бер тәгәрмәчле кул арбасы).

**ТАЩИ'ТЬ** *несов.*— 1. (сөйрәп, өстерәп, салып, күтәреп) алып бару, алып килү; *тащить мешок на спине* — капчыкны аркага салып алып килү; *тащить бревно* — бүрәнәне сөйрәп алып килү; 2. китерү, илтү, алып кайту, алып китү, ташу; *тащить покупки домой* — сатып алган нәрсәләрне өйгә алып кайту; 3. *перен.* алып бару, өстерәү; *тащить за руку* — кулыннан (тотып) өстерәү; 4. суыру, суырып чыгару, суырып алу; тартып чыгару, тартып алу; *тащить гвоздь из стены* — стенадан кадак тартып чыгару; 5. *перен. разг.* (*воровать*) урлау; 6. *разг.* сорамыйча алу, рөхсәтсез алу.

**ТАЩИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* бару, акрын гына бару, көч-хәл белән бару, өстерәлү, чак-чак атлап бару; *лошади с трудом тащились по песчаной дороге* — атлар комлы юлдан бик акрын гына атлап баралар иде; *собака тащилась за хозяином* — эт хуҗасы артыннан ияреп бара иде; 2. *разг.* сөйрәлеп бару; *подол платья тащился по земле* — күлмәк итәге җирдән сөйрәлеп бара иде.

**ТА'ЯНИЕ** *ср. мн.* нет — к. таять.

**ТА'ЯТЬ** *несов.*— 1. эрү; *снег тает* — кар эри; *свеча тает* — шәм эри; 2. *безл.* эретү; *сегодня тает* — бүген эретә; 3. *перен.* югалу, әкренләп бетү; әкренләп кимү; *звуки тают вдали* — тавышлар еракта югала; *силы тают* — көч акрынлап бетә; 4. *перен.* эреп китү; *таять от похвал* — мактаудан эреп китү; 5. *перен.* арыклану, хәлсезләнү, ябыгу, сулыгу, сүнә бару; *он таял на глазах* — ул күз алдында сүнә бара иде.

**ТВАРЬ** *ж.*— 1. (*живое существо*) жан иясе, тереклек иясе, мәхлук; 2. *разг. фам. вульг. презрит. бран.* (*недостойный, негодный человек*) хайван, дуңгыз. ◇ **Всякой твари по паре** *разг. шутл.* — һәрбер жан иясеннән бер пар, төрле кешеләр бар иде, төрле жанварлар бар иде (берәр халык төркеменең төрле-төрле кешеләрдән гыйбарәт булуы турында әйтелә).

**ТВЕРДИ'ТЬ** *несов. разг.*— 1. колагына туку, кат-кат әйтү, әйтеп тору, (гел бер нәрсәне генә) сөйләү; *об этом твердят все* — бу турыда бар кеше дә сөйли; 2. кат-кат укып ятлау; тәкрарлау; *твердить урок*— дәресне кат-кат укып ятлау.

**ТВЕРДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кат-кат укып ятлану, тәкрарлану.

**ТВЁРДО** *нареч.*— каты, нык, тотнаклы, катгый рәвештә; *твёрдо решить что-н.*— берәр нәрсәне катгый рәвештә хәл итү; *я в этом твёрдо убеждён* — мин моңа бик нык ышанганмын; *твёрдо стоять на своём* — үз фикереңдә нык тору; *твёрдо запомнить* — истә нык калдыру.

**ТВЕРДОЗЁМ** *м. мн.* нет, *спец.*— тоташ каты жир.

**ТВЕРДОКА'МЕННЫЙ** *книж. ритор.*— 1. *устар.* таш кебек каты, таштай; 2. *перен.* тотнаклы, чыдамлы, нык торучан (үз сүзеңдә, эшеңдә).

**ТВЕРДОЛО'БЫЙ** — 1. туң баш, аңгыра; 2. таш маңгайлы, таш баш; *твердолобые консерваторы* — таш баш консерваторлар.

**ТВЕРДОМЕ'Р** *м. тех.*— катылык үлчәгеч (резинаның катылык дәрәҗәсен билгели торган прибор).

**ТВЁРДОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ныклык, катылык; *шкала твёрдости* — катылык дәрәҗәсен күрсәтә торган шкала (җәдвәл); 2. тотнаклылык, сүзеңдә торучанлык.

**ТВЁРДЫЙ** — 1. каты; *твёрдое тело* — каты җисем; 2. *перен.* нык, ныклы, тотнаклы, каты, катгый; *твёрдые шаги* — ныклы адымнар; *твёрдые сроки* — каты сроклар; *твёрдая воля* — ныклы ихтыяр; *твёрдое решение* — катгый карар; *твёрдое знание дела* — эшне нык белү; 3. *лингв.* калын; *твёрдые согласные* — калын тартыклар. ◇ **Твёрдые цены** — үзгәрми торган бәяләр. **Твёрдый знак** — калынлык билгесе. **В здравом уме и твёрдой памяти** — зиһене таза, хәтере нык.

**ТВЕРДЫ'НЯ** *ж.*— 1. *устар.* к. крепость; 2. *перен. книж. ритор.* ныклы таяныч, ныклы терәк; *Советский Союз — твердыня дружбы народов* — Советлар Союзы — халыклар дуслыгының ныклы таянычы.

**ТВЕРДЬ** *ж. мн.* нет, *церк.-книж. устар.*— каты нигез, терәк, таяныч. ◇ **Твердь земная** — коры жир. **Твердь небесная** — күк йөзе.

**ТВИН** *м. мн.* нет — твин (киҗе-мамык яки ярым йон тукыманың бер төре).

**ТВОЙ** (твоя, твоё)— 1. синең; *твоя книга* — синең китабың; *это твоя работа* — бу синең эшең; 2. *в знач. сущ.* синеке, үзеңнеке; *твоего мне не нужно* — синеке миңа кирәкми; 3. *мн. в знач. сущ.* синекеләр, үзеңнекеләр (агай-эне, бала-чагалар, ата-аналар); *здоровы ли твои?* — синекеләр исән-саумы? *кланяйся всем твоим?* — үзеңнекеләргә сәлам әйт. ◇ **По-твоему** — синеңчә; *как по-твоему?*— синеңчә ничек? **Что твой** или *устар.* **на что твой** — нәкъ... шикелле,... мени? *собою невеличка, а песни — что твой соловей* — үзе кечкенә, ә сайравы — нәкъ сандугач сайравы шикелле.

**ТВОРЕ'НИЕ** *ср. книж.*—1. *устар. ирон. шутл.* жан иясе, зат; 2. иҗат ителгән әсәр, әсәр; *великие творения Пушкина* — Пушкинның бөек әсәрләре.

**ТВОРЁНЫЙ** *спец.*— изелгән; *творёная известь* — изелгән известь.

**ТВОРЕ'Ц** *м.*— иҗатчы, иҗат итүче, барлыкка китерүче, тудыручы; *творцы советской науки и техники* – совет фәнен һәм техникасын иҗат итүчеләр.

**ТВОРИ'ЛО** I *ср.*— 1. капкач, япкыч (мәсәләи, буаның, арыкның япкычы); 2. капкач (базга, чормага ачып төшү яки менү өчен); 3. авыз, чокыр авызы, тишек.

**ТВОРИ'ЛО** II *ср. тех.*— балчык (известь) изә торган савыт.

**ТВОРИ'ТЕЛЬНЫЙ: творительный падеж** — творительный падеж (рус теле грамматикасында күбрәк „кем белән, нәрсә белән, кем тарафыннан" дигән сорауларга җавап бирә торган килеш).

**ТВОРИ'ТЬ** I *несов.*— 1. иҗат итү, булдыру, барлыкка китерү, тудыру, кору; төзү; ярату; *творить новую жизнь* — яңа тормыш кору; 2. *книж. ритор.* или *ирон.* эшләү; *творить добро* — яхшылык эшләү; *творить чудеса* — гаҗәп эшләр эшләү. ◇ **Творить себе кумир** или **кумира из** *кого-чего* — (берәр кешене яки әйберне) үзеңә кумир санау, артык олылау, аңа табыну.

**ТВОРИ'ТЬ** II *несов. спец.*— изү; *творить известь* — известь изү; *творить тесто* — камыр изү.

**ТВОРИ'ТЬСЯ** I *несов.*— 1. *разг.* булу, эшләү, кылану, эшләнү; *что тут у вас творится?*— бу нинди эш, нишләвегез бу? 2. *страд. книж. ритор.* или *ирон.* корылу, төзелү, иҗат ителү; *у нас творится новая жизнь* — бездә яңа тормыш төзелә.

**ТВОРИ'ТЬСЯ** II *несов. страд. обл. спец.*— изелү.

**ТВОРО'Г** *м. мн.* нет — эремчек.

**ТВОРО'ЖИСТЫЙ** — эремчексыман; *творожистый осадок* — эремчексыман утырма.

**ТВОРО'ЖИТЬ** *несов. спец.*— эремчек ясау, эремчеккә әйләндерү; эремчексыман итү; *творожить молоко* — сөтне эремчеккә әйләндерү.

**ТВОРО'ЖИТЬСЯ** *несов. спец.*— 1. эремчекләнү, эремчеккә әйләнү, эремчексыманлану; 2. *страд.* эремчек ясалу, эремчеккә әйләндерелү.

**ТВОРО'ЖНИК** *м.*— к. сырник.

**ТВОРО'ЖНИЦА** *ж.*— эремчек савыты.

**ТВОРО'ЖНЫЙ** — эремчектән ясалган, эремчек...-ы; *творожный сыр* — эремчектән

ясалган сыр; *творожная масса* — эремчек массасы.

**ТВО'РЧЕСКИЙ** *книж.* — иҗат...-ы, иҗади; *творческий путь писателя* — язучының иҗат юлы.

**ТВО'РЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — 1. к. творить I в 1 знач.; 2. иҗат; *творчество Пушкина* — Пушкин иҗаты; *народное творчество* — халык иҗаты.

**ТЕА'ТР** *м.* — театр (1. *только ед.* драматик әсәрне сәхнәдә күрсәтү сәнгате; *история русского театра* — рус театрының тарихы; 2. театр бинасы; *театр оперы и балета* — опера һәм балет театры; *пойти в театр* — театрга бару; 3. *устар.* спектакль; *сегодня театра не будет* — бүген спектакль булмый; 4. (берәр язучының) барлык драматик әсәрләре; *театр А. Н. Островского* — А. Н. Островскийның барлык драма әсәрләре). ◇ **Анатомический театр** — к. анатомический. **Театр военных действий** — сугыш хәрәкәтләре театры (сугыш мәйданы, сугыш кыры).

**ТЕАТРА'Л** *м.*, **ТЕАТРА'ЛКА** *ж.* — театр һәвәскәре, театр яратучы, театр сөюче, театрга күп йөрүче.

**ТЕАТРАЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. театрализовать.

**ТЕАТРАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — сәхнәләштерү; *театрализовать роман* — романны сәхнәләштерү.

**ТЕАТРАЛИЗОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов. спец.* — сәхнәләштерелү.

**ТЕАТРА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. театральлек, ясалмалык, ясалма булу, табигый булмау, кыланчык булу; тәкәллефлелек; *театральность позы* — позаның кыланчык булуы; 2. театр сәнгате; *законы театральности* — театр сәнгате законнары.

**ТЕАТРА'ЛЬНЫЙ** — 1. театр...-ы, театрлар...-ы; *театральное искусство* — театр сәнгате; 2. *перен. неодобр.* театраль, ясалма, кыланчык, тәкәллефле; *принять театральную позу* — кыланчык поза алу.

**ТЕАТРА'ЛЬЩИНА** *ж. мн.* нет, *пренебр.* — ясалмалык, кыланчыклык.

**ТЕАТРОВЕ'Д** *м.* — театр сәнгате белгече (галим).

**ТЕАТРОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — театр сәнгате белеме.

**ТЕБЕНЁК** *м. спец.* — ияр каплавычы, ияр канаты (иярнең ике ягына өзәнге бавы өстеннән төшеп тора торган күн).

**ТЕВТО'НЕЦ** *м. истор.* — тевтон ордены рыцаре.

**ТЕВТО'НСКИЙ** — тевтон...-ы, тевтоннар...-ы; *тевтонское племя* — тевтоннар кабиләсе. ◇ **Тевтонский орден** — тевтон ордены (XII гасырда Германиядә барлыкка килгән рыцарьлар ордены).

**ТЕВТО'НЫ** *мн.* — тевтоннар (борынгы герман кабиләләренең берсе).

**ТЕ'ГА-ТЕ'ГА** *межд. разг.* — дөгә-дөгә, гәл-гәл (каз чакыру ымлыгы).

**ТЕ'ЗА** *ж.* — 1. *устар.* к. тезис 2; 2. (кайбер илләрдә) диссертация.

**ТЕЗАВРИ'РОВАНИЕ** *ср. мн.* нет — к. тезаврировать.

**ТЕЗАВРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон.* — тезаврирлау, тезаврировать итү (акчаны яки капиталны банкка яки саклык кассасына салмыйча, өйдә саклап тоту).

**ТЕЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.* — тезис рәвешендә язып кую, тезислау.

**ТЕЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — тезис рәвешендә язып куелу.

**ТЕ'ЗИС** *м.* — тезис (1. соңыннан исбатлана торган положение, раслау; 2. *филос.* Гегельнең идеалистик философиясендә үсеш процессының башлангыч пункты; тезис, антитезис, синтез дип йөртелгән триаданың беренче моменты).

**ТЁЗКА** *ж. разг.* — адаш (бер исемдәге кеше).

**ТЕЗОИМЕНИ'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *офиц. торж. устар.* — исем бәйрәме (зур дәрәҗәле кешенең, мәсәлән, патша семьясы кешеләренең исем кушкан көне бәйрәме).

**ТЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет — теизм (галәмне алла яраткан һәм аны идарә итеп тора дип раслаучы дини философик агым).

**ТЕИ'СТ** *м. филос.* — теизм тарафдары.

**ТЕИСТИ'ЧЕСКИЙ** *филос.* — теизм...-ы, теист...-ы, теистик; *теистическое суеверие* — теистик хорафат.

**ТЕКИ'НКА** *ж.* — текин хатын-кызы.

**ТЕКИ'НСКИЙ** — текин...-ы; *текинский ковёр* — текин келәме; *текинская лошадь* — текин аты.

**ТЕКИ'НЦЫ** *мн.* — текиннар (төркмән кабиләләренең иң зурысы).

**ТЕКСТ** *м.* — текст (1. берәр кеше тарафыннан язылган яки сөйләнгән сүзләр; *текст сочинений Пушкина* — Пушкин әсәрләренең тексты; 2. берәр әсәрдән алынган өземтә; 3. *тип.* наборга бирелгән материалның сурәтләреннән һәм чертёжларыннан башка төп өлеше; 4. *только ед. тип.* 20 пунктлы матбугат хәрефе, шрифты; 5. *муз.* музыка әсәренең сүзләре; *романс на текст Пушкина* — Пушкин текстына язылган романс).

**ТЕКСТИ'ЛЬ** *м.* — 1. *только ед. собир.* текстиль, тукыма; 2. *простореч.* к. текстильщик.

**ТЕКСТИ'ЛЬНЫЙ** — текстиль...-ы; *текстильная фабрика* — текстиль фабрикасы.

**ТЕКСТИ'ЛЬЩИК** *м.* — текстильщик, тукучы (туку промышленносте эшчесе).

**ТЕКСТИ'ЛЬЩИЦА** *ж.* — текстильщица, тукучы (туку промышленностенда эшләүче хатын-кыз).

**ТЕКСТОВО'Й** — текст...-ы; *текстовой набор* — текст наборы (текст хәрефләре белән җыю).

**ТЕКСТО'ЛОГ** *м. филол.* — текстолог, текстология белгече.

**ТЕКСТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — текстология...-ы, текстологик; *текстологическое исследование* — текстологик тикшеренү.

**ТЕКСТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *филол.* — текстология (филологиянең текстларны өйрәнү, ачыклау һәм аларны фәнни нигездә бастырып чыгару эшләре белән шөгыльләнә торган бүлеге).

**ТЕКСТУА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — сүзгә-сүз булу, сүзгә-сүзлелек.

**ТЕКСТУА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — текстуаль, бермә-бер, сүзгә-сүз, нәкъ тексттагыча; *текстуальный перевод* — сүзгә-сүз тәрҗемә.

**ТЕКТО'НИКА** *ж. мн.* нет, *геол.* — тектоника (1. геология фәненең җир кабыгын һәм анда булып тора торган процессларны өйрәнә торган бүлеге; 2. җир кабыгының төзелеше һәм анда булып торган үзгәрешләр).

**ТЕКТОНИ'ЧЕСКИЙ** *геол.* — тектоника...-ы; тектоник; *тектонические явления* — тектоник күренешләр.

**ТЕКУ'ЧЕСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. *физ.* агучанлык; *текучесть жидких тел* — сыек җисемнәрнең агучанлыгы; 2. *перен.* алмашынып тору, алмашынучанлык; *текучесть рабочей силы* — эшче көченең (эшчеләрнең) алмашынучанлыгы.

**ТЕКУ'ЧИЙ** — 1. ага торган, агым..., сыек; *текучие тела* — ага торган җисемнәр; 2. *перен.* алмашынып тора торган; *текучая рабочая сила* — алмашынып тора торган эшчеләр.

**ТЕКУ'ЧКА** *ж. обл. спец.* — 1. агачтан агып чыккан сумала; 2. орлыгы коела торган җитен.

**ТЕКУ'ЩИЙ** *книж.* — 1. ага торган, агым, агучы; *медленно текущая река* — акрын ага торган елга; 2. *перен.* хәзерге, шушы көндәге, шушы; *текущий момент* — хәзерге момент; 3. *перен.* гадәттәге, көндәлек, агымдагы; *текущие дела* — агымдагы эшләр; *текущий счёт* — агымдагы счёт.

**ТЕЛЕАВТО'ГРАФ** *м. тех.* — телеавтограф (кулъязмаларны, чертёжларны һ. б. телеграф аша тапшыра торган аппарат).

**ТЕЛЕВЕЩА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.* — телевещание (радио һәм телевидение ярдәмендә еракка сурәт тапшыру).

**ТЕЛЕВИ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет, *тех.* — телевидение (рәсемне, сурәтне радио һәм телеграф чыбыклары ярдәмендә ерактан күрсәтү, күрү).

**ТЕЛЕВИ'ДНЫЙ** *тех.* — к. телевизионный.

**ТЕЛЕВИЗИО'ННЫЙ** *тех.* — телевидение ...-ы, телевизион; *телевизионный центр* — телевизион үзәк.

**ТЕЛЕВИ'ЗИЯ** *ж. мн.* нет — к. телевидение.

**ТЕЛЕВИ'ЗОР** *м. тех.* — телевизор (рәсемне, сурәтне ерактан кабул итә торган радиоалгыч).

**ТЕЛЕВИ'ЗОРНЫЙ** *тех.* — телевизор...-ы; *телевизорный экран* — телевизор экраны.

**ТЕЛЕ'ГА** *ж.* — арба.

**ТЕЛЕГРА'ММА** *ж.* — телеграмма.

**ТЕЛЕГРА'Ф** *м.* — телеграф (1. телеграф аппараты; 2. телеграф идарәсе; 3. телеграф бинасы). ◇ **Беспроволочный телеграф** — к. радиотелеграф.

**ТЕЛЕГРАФИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — телеграм(ма) җибәрү, телеграм(ма) сугу, телеграм(ма) бирү, телеграф аша хәбәр бирү.

**ТЕЛЕГРАФИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — телеграм(ма) җибәрелү, телеграм(ма) бирелү, телеграм(ма) сугылу, телеграф аша хәбәр бирелү.

**ТЕЛЕГРАФИ'СТ** *м.* — телеграфист (телеграфта эшләүче).

**ТЕЛЕГРАФИ'СТКА** *ж.* — телеграфистка (телеграфта эшләүче хатын-кыз).

**ТЕЛЕГРА'ФИТЬ** *сов.* и *несов.* *разг.* — к. телеграфировать.

**ТЕЛЕГРАФИ'Я** *ж. мн.* нет, *спец.* — телеграфия (телеграф эшләре, телеграф сигналлары бирү техникасы).

**ТЕЛЕГРА'ФНЫЙ** — телеграф...-ы; *телеграфное сообщение* — телеграф хәбәре.

**ТЕЛЕ'ЖКА** *ж.* — кечкенә арба, бәләкәй арба, кул арбасы.

**ТЕЛЕ'ЖНИК** *м.* — арба ясаучы, арба остасы.

**ТЕЛЕ'ЖНЫЙ** — арба...-ы; *тележный след* — арба эзе.

**ТЕЛЕКИНО'** *ср. нескл. тех.* — телекино (телевизор аша кино күрсәтү).

**ТЕЛЕМЕХА'НИКА** *ж. мн.* нет, *тех.* — телемеханика (яктылык сигналлары, электр сигналлары яки радио ярдәмендә ерактан торып механизмнар белән идарә итү).

**ТЕЛЕМЕХАНИ'ЧЕСКИЙ** *тех.* — 1. телемеханика...-ы, телемеханик; 2. телемеханика аркылы; *телемеханическое устройство* — телемеханик корылма; *телемеханическое управление гидростанциями* — гидростанцияләрне телемеханика аркылы идарә итү.

**ТЕЛЁНОК** *м.* — бозау. ◇ **Послать, куда Макар телят не гонял** *разг. фам.* — җир читенә җибәрү, бик еракка җибәрү.

**ТЕЛЕОБЪЕКТИ'В** *м. фот.* — телеобъектив (ерактан зурайтып күрсәтә торган фотографик объектив).

**ТЕЛЕОЗА'ВР** *м. палеон.* — телеозавр (калдыклары гына җир астыннан табыла торган бик зур диңгез крокодилы).

**ТЕЛЕОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *филос.* телеология...-ы, телеологик; *телеологическое учение* — телеологик тәгълимат; 2. *науч.* берәр максатка омтылышлы, берәр максатка юнәлдерелгән.

**ТЕЛЕОЛОГИ'ЧНЫЙ** *науч.* — к. телеологический 2.

**ТЕЛЕОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — телеология (1. табигатьтә бөтен нәрсә үз максатына туры китереп яратылган һәм һәртөрле үсеш электән үк билгеләп куелган максатларны тормышка ашырудан гыйбарәт дип раслый торган идеалистик тәгълимат; 2. *науч.* берәр нәрсәнең эчке табигате, характеристикасы буларак бер максатка омтылу, юнәлү).

**ТЕЛЕПА'ТИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — телепатия (ерактагы әйберләрне һәм кешенең фикерләрен ерактан торып та күрү яки белү мөмкин дип раслый торган, фәнгә каршы уйдырма).

**ТЕЛЕПЕ'НЬ** *м. обл.* — 1. озын кистән; 2. кыңгырау теле; 3. *перен.* сүлпән кеше; 4. *перен.* аңгыра, тинтәк кеше.

**ТЕЛЕПЕРЕДА'ТЧИК** *м. тех.* — телетапшыргыч (телевизорның тапшыра торган өлеше).

**ТЕЛЕСА'** *ед. нет, разг. шутл. ирон.*— симез, калын гәүдә.

**ТЕЛЕСКО'П** *м.*— телескоп (1. *астр.* йолдызларны карау приборы; 2. *зоол.* алтын балыклар төреннән акай күзле балык).

**ТЕЛЕСКОПИ'ЧЕСКИЙ** — 1. телескоп...-ы; *телескопическая труба* — телескоп трубасы; 2. *астр.* телескоп аша гына күреп була торган, телескопик.

**ТЕЛЕСКОПИ'Я** *ж. мн.* нет, *астр.*— телескопия, телескоп аша карап йолдызларны күзәтү.

**ТЕЛЕСКО'ПНЫЙ** *астр.*— к. телескопический 1.

**ТЕЛЕ'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *книж. устар.* матдилек, материальлек, җисманилек; *телесность мира* — галәмнең матдилеге; 2. *простореч. фам. шутл.* юанлык, симезлек, итләчлек.

**ТЕЛЕ'СНЫЙ** — 1. җисем...-ы, җисемлек ...-ы; 2. тән...-ы, физик; *телесное наказание* — тән җәзасы; 3. *перен. книж. устар.* материаль, матди...; *телесный мир* — материаль дөнья. ◇ **Телесный цвет** — тән төсендәге, тән төсе.

**ТЕЛЕТА'ЙП** *м. тех.*— телетайп (зур язу машинкасы рәвешендәге хәреф басу аппараты, аның ярдәмендә текстны еракка тапшырырга мөмкин, текстны кабул итү исә механик рәвештә бара).

**ТЕЛЕФО'Н** *м.*— телефон.

**ТЕЛЕФОНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— к. телефонизировать.

**ТЕЛЕФОНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— телефонлаштыру, телефон кертү, телефон кую.

**ТЕЛЕФОНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— телефонлаштырылу, телефон кертелү, телефон куелу.

**ТЕЛЕФОНИ'РОВАТЬ** *несов.*— телефон аша хәбәр итү, телефоннан әйтү.

**ТЕЛЕФОНИ'СТ** *м.*— телефонист, телефонда эшләүче.

**ТЕЛЕФОНИ'СТКА** *ж.*—телефонистка (телефонда эшләүче хатын-кыз).

**ТЕЛЕФОНИ'Я** *ж. мн.* нет, *спец.*— телефон техникасы.

**ТЕЛЕФО'ННЫЙ** — 1. телефон...-ы; *телефонный аппарат* — телефон аппараты; 2. телефон аша...; *телефонные разговоры* — телефон аша сөйләшүләр.

**ТЕЛЕФОНОГРА'ММА** *ж.*— телефонограмма (телефон аша әйтеп яздырылган хәбәр); *передать телефонограмму* — телефонограмма бирү.

**ТЕЛЕФОТОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — телефотография (телеобъектив ярдәмендә ерактан фотографиягә төшерү, рәсемгә төшерү).

**ТЕЛЕ'Ц** *м. церк.-книж. устар.*— бозау. ◇ **Золотой** или **златой телец** *книж. ритор.*— 1. алтын, акча, байлык; 2. акча көче, алтын көче.

**ТЕЛЕШО'М** *нареч. обл.*— ялангач, шәрә килеш.

**ТЕЛИ'ТЬСЯ** *несов.*— бозаулау.

**ТЕЛИ'ЦА** *ж. церк.-книж. устар.* — к. телец, тёлка.

**ТЁЛКА** *ж.*— 1. тана бозау; 2. тана сыер, башмак.

**ТЕЛЛУ'Р** *м. мн.* нет, *хим.*— теллур (көмешсыман ак төстәге кристалл, химик элемент).

**ТЕ'ЛО** *ср.*— 1. *физ. мат.* җисем; *твёрдое тело* — каты җисем; *жидкое тело* — сыек җисем; *геометрическое тело* — геометрик җисем; 2. тән, гәүдә; *части тела* — тән әгъзалары; 3. *воен.* көпшә; *тело пулемёта* — пулемёт көпшәсе. ◇ **Войти в тело** — ит куну, тәнгә ит керү, калынаю, юанаю. **Нагулять тело** — көрәю, симерү. **Лошади в теле** — атлар көр. **Спасть с тела** *разг.*— ябыгу, ябыгып китү. **Душой и телом** — җаным-тәнем белән. **Держать в чёрном теле** — көн күрсәтмәү, кимсетү. **Инородное тело** — чит нәрсә, чит җисем (организмга кереп калган чит җисем).

**ТЕЛОГРЕ'ЙКА** и **ТЕЛОГРЕ'Я** *ж.*— телогрейка, тән җылыткыч.

**ТЕЛОДВИЖЕ'НИЕ** *ср. книж.*— тән хәрәкәте, әгъзалар хәрәкәте.

**ТЕЛО'К** *м. простореч.*— к. телёнок.

**ТЕЛОСЛОЖЕ'НИЕ** *ср. книж.*— тән төзелеше, сын, фигура, гәүдә; *красивое телосложение* — матур гәүдә; *человек крепкого телосложения* — тән төзелеше нык кеше.

**ТЕЛОХРАНИ'ТЕЛЬ** *м. офиц. устар.*— тән сакчысы, шәхси сакчы.

**ТЕЛУ'ШКА** *ж. разг.*— к. тёлка. ◇ **За морем телушка — полушка, да рубль перевозу** *посл.*— Агыйделнең аръягында бер иннәгә бер сыер.

**ТЕ'ЛЬНИК** *м.*— 1. эчке күлмәк; 2. *устар.* муен тәресе (муенга эчтән тагып йөри торган тәре).

**ТЕ'ЛЬНЫЙ** — 1. *простореч.* эчке; *тельная рубаха* — эчке күлмәк; 2. *разг.* тән ...-ы; тән төсле; *чулки тельного цвета* — тән төсле оек.

**ТЕЛЬНЯ'ШКА** *ж. простореч. фам.*— тельняшка (матросларның эчке күлмәге).

**ТЕ'ЛЬЦЕ** *ср.*— 1. *разг. фам.* к. тело 2; 2. *обл. только ед.* йомшак өлеш (җимешнең йомшак өлеше); 3. *обл.* йомыркадагы яралгы; 4. *обл.* йомырканың очлы башы.

**ТЕЛЯ'ТИНА** *ж. мн.* нет — 1. бозау ите, тана ите; 2. *перен. простореч. фам.* бозау, уҗым бозавы (аңгыра, тинтәк кеше).

**ТЕЛЯ'ТНИК** *м.*— 1. бозау абзары; 2. бозау караучы; 3. бозаулар белән сату итүче.

**ТЕЛЯ'ТНИЦА** *ж.*— к. телятник 2, 3.

**ТЕЛЯ'ЧИЙ** — 1. бозау...-ы; *телячьи ножки* — бозау аяклары; 2. бозау итеннән пешерелгән; *телячьи котлеты* — бозау итеннән пешерелгән котлет. ◇ **Телячий восторг** — урынсызга шатлану, бернинди сәбәпсез куану. **Телячьи нежности** — төче назланулар, тозсыз назланулар.

**ТЕМ** *союз* — шулкадәр, шулхәтле; *чем ночь темней, тем ярче звёзды* (Майков) — төн никадәр караңгы булса, йолдызлар шулкадәр якты; яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен (Тукай тәрҗемәсе), ◇ **Тем более** — бигрәк тә. **Тем лучше** —

бик әйбәт. **Тем не менее** — шулай була торып, шулай булса да, шуңа карамастан.

**ТЕ'МА** *ж.* — тема (1. әсәрнең, речьнең һ. б. төп предметы; *тема произведения* — әсәрнең темасы; 2. *муз.* музыка әсәренең төп көе; 3. *лингв.* ясалма фигыль нигезе).

**ТЕМА'ТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— тематика (барлык темаларның җыелмасы); *современная тематика* — хәзерге заман тематикасы.

**ТЕМАТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— тема...-ы, тематика...-ы, тематик; *тематический план*— тематик план.

**ТЕМБР** *м.*— тембр (тавышның характерлы сыйфаты).

**ТЕ'МБРОВЫЙ** — тембр...-ы; *тембровые различия инструментов* — музыка коралларының тембр үзенчәлекләре (тембр ягыннан төрле булуы).

**ТЕМЕННО'Й: теменная кость** — баш түбәсе сөяге.

**ТЕ'МЕНЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— караңгылык, кап-караңгы; *в лесной чаще стояла темень* — куе урманда кап-караңгы иде.

**ТЕМЛЯ'К** *м. воен.*— темляк, бөлдерге (кылыч яки хәнҗәр тоткасына тагылган чуклы тасма).

**ТЁМНАЯ** *ж. в знач. сущ. устар.*— арестантлар бүлмәсе, карцер.

**ТЕМНЕ'ТЬ** *несов.*— 1. каралу, карала төшү; *краски на картинах от времени темнеют* — күп вакыт үтү сәбәпле картиналарның буяулары карала; 2. *безл.* караңгылану, караңгы төшү; *темнеет, пора спать* — караңгы төшә, йокларга вакыт; 3. кара булып күренү, каралып күренү, кара кучкылланып тору (күренү); *вдали темнеют горы* — ерakta таулар кара кучкылланып тора.

**ТЕМНЕ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— к. темнеть 3.

**ТЕ'МНИК** *м.*— темалык (сочинениеләр, рефератлар һ. б. ш. исемлеге).

**ТЕМНИ'ТЬ** *несов.*— каралту, карайту, күләгәләү, карайта төшү.

**ТЕМНИ'ЦА** *ж. книж. поэт. устар.*— зиндан, төрмә.

**ТЕМНИ'ЧНЫЙ** — зиндан...-ы, төрмә...-ы; *темничный мрак* — зиндан караңгылыгы.

**ТЕМНО'** — 1. *нареч.* төшенә алмаслык итеп, аңлаешсыз, караңгы; *темно выражаться* — аңлаешсыз сөйләү; 2. *в знач. сказ.* караңгы; *темно в глазах* — күз алдым караңгы.

**ТЕМНОТА'** *ж.*— 1. караңгылык, караңгы; *темнота ночи* — төннең караңгылыгы; *вернуться домой до наступления темноты* — караңгы төшкәнче өйгә кайту; 2. (*тёмное пятно*) кара тап; 3. *перен.* наданлык, томаналык, каралык.

**ТЁМНЫЙ** — 1. караңгы; *тёмная комната* — караңгы бүлмә; *тёмная ночь* — караңгы төн; 2. кара, кара төстәге, карасу төстәге; *тёмные волосы* — кара чәч; *тёмное платье* — карасу төстәге күлмәк; 3. *перен.* аңлаешсыз, шикле, караңгы; *тёмные места в тексте* — текстның аңлаешсыз урыннары; *тёмное дело* — караңгы эш; 4. *перен.* кайгылы, хәсрәтле, күңелсез, караңгы, сүрән; *с тёмным от горя лицом* — кайгыдан караңгыланган чырай белән; 5. усал, җинаятьчел, кара, явыз; *тёмные силы реакции* — реакциянең кара көчләре; 6. *обл. старин.* сукыр; *он сроду тёмный* — ул тумыштан сукыр; 7. *перен.* надан, томана, белемсез, кара; *тёмные люди* — надан кешеләр. ◇ **Темна вода в облацех** *шутл.*— аңлаешсыз, алла белсен. **Тёмное пятно** *перен.*— кара тап (1. ачыкланмаган, билгеле булмаган, караңгы нәрсә; 2. хурлыклы бер нәрсә). **Темным-темно** — кап-караңгы, дөм-караңгы.

**ТЕМП** *м.*— темп (1. *муз.* музыка әсәрен башкарганда тизлек, тизлек дәрәҗәсе; *исполнить музыкальную пьесу в быстром темпе* — музыкаль пьесаны тиз темпта башкару; 2. *перен.* берәр нәрсәнең тормышка ашуы, үтәлү тизлеге; *рост темпов производства* — җитештерү темпларының үсүе).

**ТЕ'МПЕРА** *ж. нескл. живоп.*— темпера (1. йомырка сарысы һәм сыек җилем яки бал кушып ясалган минерал буяу; 2. шундый буяу белән язылган картина).

**ТЕМПЕРА'МЕНТ** *м.*— темперамент (1. кешенең тышкы дөнья ярсыткычларына карата тәэсирләнүен һәм аның тышкы дөньяга реакциясен характерлый торган барлык психик сыйфатлары; *меланхолический темперамент* — меланхолик темперамент; 2. *только ед.* дәрт, гайрәт; *человек без темперамента* — темпераментсыз кеше, дәртсез кеше). ◇ **Жертва общественного темперамента** *ритор. эвф. устар.*— уйнашчы хатын, фахишә.

**ТЕМПЕРА'МЕНТНЫЙ** — темпераментлы, дәртле; кызу, кызу канлы; *темпераментный актёр* — темпераментлы актёр.

**ТЕМПЕРАТУ'РА** *ж.*— температура (җылылык, салкынлык дәрәҗәсе); *комнатная температура* — бүлмә температурасы; *повышенная температура* — күтәренке температура.

**ТЕМПЕРАТУ'РИТЬ** *несов. разг.*— температура күтәрелү; *меня по вечерам температурит* — кичләрен минем температурам күтәрелә.

**ТЕМПЕРАТУ'РНЫЙ** — температура...-ы; *температурный показатель* — температура күрсәткече; *температурная кривая* — температура сызыгы (температураның күтәрелүен һәм төшүен белдерә торган сызык).

**ТЕМЬ** *ж. мн.* нет, *разг. поэт.*— к. тьма.

**ТЕ'МЯ** *ср. мн.* нет — баш түбәсе, баш сөягенең түбә өлеше.

**ТЕМЯ'ШИТЬ** *несов. обл.* — түбәләү, төю (йодрык белән кыйнау мәгънәсендә).

**ТЕНА'КЛЬ** *м. тип.* — тенакль, кыстыргыч (типографиядә текстны җыйганда кулъязма битен кыстыру өчен).

**ТЕ'НДЕМ** *м.* — тендем (1. *только ед. тех.* берәр нәрсәнең төрле кисәкләрен бер-бер артлы урнаштыру; 2. бер валга тәэсир итә торган ике янсә берничә цилиндры бер-бер артлы куелган пар машинасы; 3. *спец.* ике кешелек велосипед; 4. *спец.* очка җиккән пар атлы ике тәгәрмәчле арба).

**ТЕНДЕНЦИО'ЗНИЧАТЬ** *несов разг.* не-

*одобр.* — тенденциозлану, тенденциозлык белән эш итү.

**ТЕНДЕНЦИО'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — тенденциялелек, тенденциозлык, берьяклылык (алдан уйланган берьяклы фикер; эшнең төп мәгънәсе белән бәйләнмәгән һәм укучыга, тыңлаучыга ирексезләп тагылган яки тәкъдим ителгән караш).

**ТЕНДЕНЦИО'ЗНЫЙ** *книж.* — тенденцияле, тенденциоз, берьяклы; *тенденциозный роман* — тенденциоз роман.

**ТЕНДЕ'НЦИЯ** *ж. книж.* — тенденция (1. идея, фикер; *основная тенденция книги* — китапның төп идеясе; 2. *неодобр. устар.* берьяклы фикер; әдәби, гыйльми әсәрләрдә берьяклы фикер, идея; эшнең төп мәгънәсе белән бәйләнмәгән һәм укучыга, тыңлаучыга ирексезләп тагылган яки тәкъдим ителгән караш; 3. омтылыш, тоткан юл, үсеш юнәлеше; *прогрессивные тенденции* — прогрессив тенденцияләр).

**ТЕ'НДЕР** *м.* — тендер (1. *ж.-д.* паровозга беркетеп ясалган су һәм күмер вагоны; 2. *мор.* бер мачталы җилкәнле судно).

**ТЕНЕВО'Й** — 1. күләгәле, күләгә төшә торган; *теневая сторона улицы* — урамның күләгәле ягы; 2. *перен.* кире, тискәре; *теневая сторона дела* — эшнең кире ягы.

**ТЕНЕЛЮ'Б** *м. бот.* — күләгә яратучы (үсемлек).

**ТЕНЕЛЮБИ'ВЫЙ** *бот.*—күләгә яратучан.

**ТЕНЕРИ'Ф** *м. мн.* нет — тенериф (кызыл аракының бер сорты).

**ТЕНЁТА** *мн. устар.*— ау ятьмәсе, тозак.

**ТЕНЁТНИК** *м. зоол.* — үрмәкүч.

**ТЕНИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет — күләгәлелек.

**ТЕНИ'СТЫЙ** — күләгәле, күләгә күп төшә торган; *тенистый сад* — күләгә күп төшә торган бакча.

**ТЕНИ'ТЬ** *несов. живоп. арго* — күләгә салу, күләгә төшерү.

**ТЕ'ННИС** *м., мн.* нет, *спорт* — теннис (кечкенә тупларны өстәл өстендә кечкенә көрәк— ракетка белән бәреп уйнау).

**ТЕННИСИ'СТ** *м.*, **ТЕННИСИ'СТКА** *ж. спорт.* — теннис уйнаучы, теннис уены белгече.

**ТЕ'ННИСНЫЙ** *спорт.* — теннис ...-ы; *теннисный мяч* — теннис тубы.

**ТЕ'НОР** *м.* — тенор (1. ирләрдә иң нечкә тавыш; 2. шул тавыш белән җырлаучы; 3. *муз.* тынлы оркестрда музыка коралы).

**ТЕНОРО'ВЫЙ** — тенор ...-ы; *теноровый репертуар* — тенор репертуары.

**ТЕНТ** *м.* — тент (пароход палубасында, диңгез буенда кояштан саклану өчен корыла торган чатыр).

**ТЕНЬ** *ж.* — 1. *только ед.* күләгә, шәүлә; *сидеть в тени* — күләгәдә утыру; *тень от дерева* — агач күләгәсе; 2. *перен.* чит, күләгә; *держаться в тени* — читтә тору; *остаться в тени* — күләгәдә калу; 3. *перен.* эз, әсәр, чаткы; *на лице промелькнула тень сомнения* — йөзендә шикләнү эзе чагылып китте; 4. *перен. только ед.* тап, шик; *бросить тень на кого-н.* — берәүгә тап төшерү; *тень падает на него* — шик аңа төшә; *у меня нет ни тени сомнения в его правоте* — минем аның хаклы булуында бер тамчы да шигем юк (һичбер шигем юк). ◇ **Наводить тень** *разг.* — күрәләтә ялгыштырырга маташу, күрәләтә бутарга маташу. **От него осталась одна тень** — аның коры сөяге генә калган, бик ябыккан.

**ТЕ'НЬКАТЬ** *несов. разг.* — теңкелдәү, чеңкелдәү.

**ТЕОГО'НИЯ** *ж. мн.* нет — теогония (аллаларның килеп чыгуы турында мифлар җыентыгы).

**ТЕОДОЛИ'Т** *м. геодез.* — теодолит (җир үлчәү, план төшерү эшендә кулланыла торган почмак үлчәү коралы).

**ТЕОКРАТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — теократия ...-ы, теократик; *теократический строй* — теократик строй.

**ТЕОКРА'ТИЯ** *ж. книж.* — теократия (1. власть дин башлыклары кулында булган дәүләт идарәсе; 2. шул ысулда идарә ителә торган дәүләт).

**ТЕО'ЛОГ** *м. книж.* — теолог (теология белән шөгыльләнүче кеше).

**ТЕОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — теология ...-ы, теологик; *теологический вывод* — теологик нәтиҗә.

**ТЕОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — теология, илаһият (алла һәм дин догматлары турында дини тәгълимат).

**ТЕОРЕ'МА** *ж. науч.* — теорема (аксиомаларга яки моңарчы исбат ителгән башка положениеләргә нигезләнгән дәлилләр юлы белән дөреслеге билгеләнгән кагыйдә); *доказать теорему* — теореманы исбат итү.

**ТЕОРЕТИЗИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — 1. теоретик мәсьәләләр белән шөгыльләнү; 2. *неодобр.* коры теориягә бирелү, коры теория белән шөгыльләнү.

**ТЕОРЕ'ТИК** *м.* — теоретик (белемнең яки эшчәнлекнең билгеле бер өлкәсендә теория мәсьәләләре белән шөгыльләнүче кеше).

**ТЕОРЕТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. теория ...-ы, теоретик; *теоретические вопросы* — теоретик мәсьәләләр; 2. теориягә генә нигезләнгән, теоретик.

**ТЕОРЕТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. неодобр.*— теориягә генә нигезләнгән булу, абстрактлык.

**ТЕОРЕТИ'ЧНЫЙ** *книж. неодобр.* — теориягә генә нигезләнгән, абстракт.

**ТЕО'РИЯ** *ж.* — теория (1. кешелек дөньясының практикасын һәм тәҗрибәсен гомумиләштергән, вакыйгаларның һәм фактларның эчке бәйләнешләрен аңлау һәм аларга җәмгыять интересларыннан чыгып тәэсир итү мөмкинлекләре бирә торган тәгълимат; *теория марксизма-ленинизма* — марксизм-ленинизм теориясе; *теория познания* — танып-белү теориясе; 2. фәннең теге яки бу тармагы, шулай ук берәр төрле һөнәрнең барлык кагыйдәләре; *теория относительности* — нисбилек теориясе; *теория вероятностей* — ихтималлыклар теориясе).

**ТЕОСО'Ф** *м.*, **ТЕОСО'ФКА** *ж.* — теософ, теософия тарафдары.

**ТЕОСО'ФИЯ** *ж. мн.* нет — теософия, тасаввыф (мистик юллар белән аллага ирешү һәм „теге дөнья" белән бәйләнеш тоту мөмкинлеге бар дигән дини мистик тәгълимат).

**ТЕПЕ'РЕШНИЙ** *разг.* — хәзерге; *тепе-решние люди* — хәзерге кешеләр.

**ТЕПЕ'РИЧА** *нареч. простореч. обл.* — к. теперь.

**ТЕПЕ'РЬ** *нареч.* — хәзер, хәзер инде; *теперь жить хорошо* — хәзер тормыш яхшы; *теперь дело пойдёт хорошо* — хәзер инде эш яхшы барыр.

**ТЁПЛЕНЬКИЙ** *разг.* — жылы гына; *выдался тёпленький денёк* — жылы гына көн туры килде. ◇ **Тёпленькое местечко** или **место** *разг.* — жылы урын, тыныч урын (борчылмыйча гына акча табып яши торган урын, җиңел акча кылә торган урын).

**ТЕПЛЕ'ТЬ** *несов.* — жылыту, жылыну; *на дворе теплеет* — тышта көн жылына, тышта жылыта.

**ТЕ'ПЛИТЬ** *несов. устар. обл.* — **1.** яндыру; *теплить свечу* — шәм яндыру; **2.** эретү; *теплить воск* — балавыз эретү.

**ТЕ'ПЛИТЬСЯ** *несов.* — елтыр-елтыр гына янып тору, сүнәр-сүнмәс кенә янып тору; *теплится свеча* — сүнәр-сүнмәс кенә шәм янып тора. ◇ **Теплится надежда** — әле өмет чаткысы бар.

**ТЕПЛИ'ЦА** *ж.* — теплица, жылыткыч (кыш һәм яз көне яшь үсемлекләрне суыктан саклап үстерү өчен хәзерләнгән корылма).

**ТЕПЛИ'ЧНЫЙ** — теплица ...-ы, теплицада үстерелгән, жылыткычта үстерелгән; *тепличный цветок* — теплицада үстерелгән чәчәк. ◇ **Тепличный цветок** или **тепличное растение** *перен.* — тормышка сәләтсез кеше.

**ТЕПЛО'** I *ср. мн.* нет — **1.** жылы; *держать ноги в тепле* — аякларны жылыда тоту; **2.** *физ.* жылылык; *на улице один градус тепла* — тышта бер градус жылылык; **3.** *перен.* к. теплота 2.

**ТЕПЛО'** II — **1.** *нареч.* жылы; *он был одет тепло* — ул жылы киенгән иде; **2.** *перен.* ягымлы, жылы, дусларча; *тепло встретить кого-н.* — берәр кешене дусларча каршы алу; **3.** *в знач. сказ. безл.* жылы; *в моей комнате всегда тепло* — минем бүлмәдә һәрвакыт жылы.

**ТЕПЛОВО'З** *м. ж.-д.* — тепловоз (эчке янулы двигатель көче белән хәрәкәткә килә торган локомотив).

**ТЕПЛОВО'Й** — жылылык ...-ы; *тепловой луч* — жылылык нуры; *тепловая энергия* — жылылык энергиясе.

**ТЕПЛОЁМКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.* — жылылык сыемы (берәр җисемне бер градуска жылыту өчен кирәк булган жылылык күләме).

**ТЕПЛОИЗОЛЯЦИО'ННЫЙ** *тех.* — жылылык үткәрми торган; *теплоизоляционный материал* — жылылык үткәрми торган материал.

**ТЕПЛОКРО'ВНЫЕ** *мн. зоол.* — жылы канлылар (кан жылылыгы һәрвакыт чагыштырмача югары һәм гел бер дәрәҗәдә була торган хайваннар).

**ТЕПЛОЛЮ'Б** *м. спец.* — жылы ярата торган, жылы сөючән, жылыда үсә торган, жылы яратучы, жылыда үсүче.

**ТЕПЛОПЕРЕДА'ЧА** *ж. мн.* нет, *физ.* — жылылык тапшыру, жылылык күчү; *коэффициент теплопередачи* — жылылык күчү коэффициенты.

**ТЕПЛОПРОВО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.* — жылы үткәрүчелек; *коэффициент теплопроводности* — жылы үткәрүчелек коэффициенты.

**ТЕПЛОПРОВО'ДНЫЙ** *физ.* — жылылык үткәрә торган, жылы үткәрүче; *теплопроводные тела* — жылы үткәрүче җисемнәр.

**ТЕПЛОПРОЗРА'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.* — жылылык нурларын үткәрүчелек (инфракызыл нурларны йотмый үткәрү сәләте).

**ТЕПЛОТА'** *ж. мн.* нет — **1.** *физ.* жылылык; *единица теплоты* — жылылык берәмлеге; *скрытая теплота* — яшерен жылылык; **2.** *перен.* дусларча (лык), ачыклык, жылылык, ягымлылык; *он говорил о тебе с большой теплотой* — ул синең турында бик жылы сөйләде, бик дусларча сөйләде.

**ТЕПЛОТВО'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.* — жылылык бирү сәләте, жылылык бирү; *теплотворность топлива* — ягулыкның жылылык бирү сәләте.

**ТЕПЛОТВО'РНЫЙ** *физ.*: **теплотворная способность** — жылылык бирү сәләте.

**ТЕПЛОТЕ'ХНИК** *м.* — теплотехник (теплотехника белгече).

**ТЕПЛОТЕ'ХНИКА** *ж. мн.* нет, *тех.* — теплотехника (техниканың жылылыктан һәм пардан рациональ файдалану мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган бүлеге).

**ТЕПЛОТЕХНИ'ЧЕСКИЙ** *тех.* — теплотехника ...-ы, теплотехник; *теплотехнический институт* — теплотехника институты.

**ТЕПЛОУСТО'ЙЧИВЫЙ** *тех.* — жылыга чыдам, жылыдан бозылмый торган; *теплоустойчивая сталь* — жылыдан бозылмый торган корыч.

**ТЕПЛОФИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *тех.* — теплофикация (**1.** эшләнелгән пар жылысын файдалану юлы белән биналарны жылыту системасы; **2.** шул системага тоташтыру).

**ТЕПЛОФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* *тех.* — теплофикацияләү, теплофикацияләштерү.

**ТЕПЛОФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* *тех.* — теплофикацияләнү, теплофикацияләштерелү.

**ТЕПЛОХО'Д** *м.* — теплоход (эчке янулы двигатель көче белән йөри торган судно).

**ТЕПЛУ'ШКА** *ж.* — теплушка (**1.** кереп жылынып чыга торган өй; **2.** жылытылган товар вагоны).

**ТЁПЛЫЙ** — **1.** жылы; *тёплая комната* — жылы бүлмә; *тёплая одежда* — жылы кием; **2.** жылытыла торган, ягыла торган; *тёплая изба* — ягыла торган өй; **3.** *перен.*

ягымлы, жылы, дусларча; *тёплые чувства* — жылы хисләр. ◇ **Тёплая компания** *разг. неодобр.* — жылы компания (1. *разг. шутл.* дуслар компаниясе; 2. авантюристлар, жуликлар компаниясе). **Тёплое место или местечко** — к. тёпленький.

**ТЕПЛЫ'НЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — бик жылы көн, жылы вакыт.

**ТЕПЛЯ'К** *м. спец.* — 1. к. теплушка 1; 2. *обл.* жылы җил; 3. *обл.* хатын-кызлар туны.

**ТЕРАПЕ'ВТ** *м.* — терапевт (эчке авырулар врачы).

**ТЕРАПЕВТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — терапевт ...-ы; терапия ...-ы; *терапевтическая клиника* — терапия клиникасы.

**ТЕРАПИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — терапия (1. теге яки бу чирне, авыруны хирургия ярдәменнән башка дәвалау; 2. медицинаның эчке авыруларны дәвалауга караган бүлеге).

**ТЕРАТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — тератология (1. *биол.* тумыштан булган гариплекне тикшерә торган фән; 2. урта гасырда фантастик образларны бергә өюдән гыйбарәт графика сәнгате стиле).

**ТЕРЕБИ'ЛЬНЫЙ** *с.-х.* — житен йолка торган, житен йолку...ы; *теребильная машина* — житен йолка торган машина.

**ТЕРЕБИ'ЛЬЩИК** *м.*, **ТЕРЕБИ'ЛЬЩИЦА** *ж.* — житен йолкучы.

**ТЕРЕБИ'ТЬ** *несов.* — 1. тарткалау, тарткалап төзәтү; *теребить складки платья* — күлмәкнең җыерчыкларын тарткалау; *теребить бороду* — сакалны тарткалау; 2. йолку; *теребить лён* — житен йолку; 3. *перен. разг.* борчу, тынычсызлау, йөдәтү; *теребить кого-н. по мелочам* — берәр кешене вак-төяк нәрсә белән йөдәтү.

**ТЕРЕБИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — йолкыну; *лён теребится машинами* — житен машиналар белән йолкына.

**ТЕ'РЕМ** *м. истор., поэт.* — терем (борынгы Русьта — башня рәвешендәге аерым йорт яки йорт өстенә манарасыман итеп салынган бина).

**ТЕРЕМО'К** *м. истор., поэт.* — к. терем.

**ТЕРЕ'ТЬ** *несов.* — 1. уу, ышку; *тереть глаза* — күзләрне ышку; 2. ваклау, изү, кыру; *тереть краски* — буяу изү; *тереть табак* — тәмәке ваклау; *тереть хрен* — керән кыру; 3. кыру, ышку; *сапог трёт ногу* — итек аякны кыра.

**ТЕРЕ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. сөртенү, ышкыну; *тереться полотенцем* — сөлге белән сөртенү; 2. ышкылу; *жернова трутся один о другой* — тегермән ташлары берберсенә ышкыла; 3. *перен. разг. фам.* ышкыну, ышкынып йөрү, буталып йөрү; *он весь век свой тёрся среди актёров* — ул гомере буе артистлар арасында буталып йөрде; 4. *страд.* сөртелү, ышкылу.

**ТЕРЗА'ТЬ** *несов. книж.* — 1. ботарлау, өзгәләү; *волк терзает ягнёнка* — бүре бәрәнне ботарлый; 2. *перен.* азаплау, җәфалау.

**ТЕРЗА'ТЬСЯ** *несов. книж.* — азаплану, өзәләнү, җәфалану.

**ТЁРКА** *ж.* — 1. угыч, кыргыч; 2. *с.-х.* тёрка (клевер сугу машинасы).

**ТЕРЛИ'К** *м. истор.* — терлик (борынгы Русьта — җиләнсыман өске кием).

**ТЕРМИДО'Р** *м. полит.* — термидор (1. Франциядә — 1793 нче елда Конвент тарафыннан кертелгән революцион календарьның 11 нче ае; 19—20 июльдән 17—18 августка туры килә; 2. Франциядә — 9 нчы термидорда — 1794 елның 27 нче июлендә — булган буржуаз контрреволюцион переворотның кыскартылган исеме).

**ТЕ'РМИН** *м.* — термин, атама (фәннең, техниканың мәгълүм бер төшенчәсен аныклап атаган сүз); *научные термины* — фән терминнары.

**ТЕРМИНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. науч.* — термин бирү, терминлаштыру, термин билгеләү.

**ТЕРМИНИ'РОВАТЬСЯ** *страд. науч.* — термин бирелү, термин билгеләнү, терминлаштырылу.

**ТЕРМИНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *науч.* — терминология...-ы, терминологик; *терминологический словарь* — терминологик сүзлек.

**ТЕРМИНОЛО'ГИЯ** *ж. науч.* — терминология (фән, техника яки сәнгатьнең аерым бер тармагына караган барлык терминнар).

**ТЕРМИ'Т** I *м. зоол.* — термит (эссе якларда зур ояларда кырмыскалар кебек күмәк яши һәм кешеләргә зур зыян китерә торган бөҗәк).

**ТЕРМИ'Т** II *м. хим. тех.* — термит (алюминийның кайбер металл окисельлары белән катнашмасы; янганда бик югары температура бирә).

**ТЕРМИ'ТНЫЙ** *хим. тех.* — термит...-ы; термит белән ...; *термитная сварка* — термит белән кыздырып ябыштыру.

**ТЕРМИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — термик, термик ысул белән ...; *термическая обработка металлов* — металларны термик ысул белән эшкәртү.

**ТЕРМО'ГРАФ** *м. метеор.* — термограф (температураның үзгәрешләрен үзе язып бара торган термометр).

**ТЕРМОДИНА'МИКА** *ж. мн.* нет, *физ.* — термодинамика (жылылыкның бүтән төр энергиягә әверелүен өйрәнә торган фән).

**ТЕРМО'МЕТР** *м.* — термометр (температура үлчәү приборы).

**ТЕ'РМОС** *м.* — термос (эчендәге әйберне жылы яки салкын килеш саклый торган савыт).

**ТЕРМОСТА'Т** *м. спец.* — термостат (автоматик регуляторлар белән даими жылылыкны бер дәрәҗәдә саклау аппараты).

**ТЕРМОТЕРАПИ'Я** *ж. мн.* нет — термотерапия (жылылык белән дәвалау ысулы).

**ТЕРМОФИ'Л** *м. биол.* — термофил (жылылык сөюче организм, бик югары температурада яши торган организм).

**ТЕРМОХИМИ'ЧЕСКИЙ** *хим.* — термохимия...-ы, термохимик.

**ТЕРМОХИ'МИЯ** *ж. мн.* нет — термохимия (химиянең химик процессларда булган

жылылык күренешләрен өйрәнә торган бүлеге).

**ТЕРМОЯ'ДЕРНЫЙ** — термик-төш...-ы; *термоядерная реакция* — термик-төш реакциясе.

**ТЕ'РМЫ** *ед.* нет, *истор.* — мунча (борынгы Римда).

**ТЁРН** *м.* — к. терновник.

**ТЕ'РНИЕ** *ср. церк.-книж. устар.* — 1. чәнечкеле үсемлек; 2. (шул үсемлектә булган) чәнечке, кылчык.

**ТЕРНИ'СТЫЙ** *книж. устар.* — чәнечкеле; *тернистый куст* — чәнечкеле куак. ◇ **Тернистый путь** *книж. ритор.* — авыр юл, кыен юл.

**ТЕРНО'ВНИК** *м. бот.* — күгән (агачы).

**ТЕРНО'ВЫЙ** — чәнечкеле; *терновый венок* — чәнечкеле чәчәкләр бәйләме. ◇ **Терновый венец** *перен. поэт. ритор.* — чәнечкеле венок (газаплану, газап чигү билгесе).

**ТЕРНОСЛИ'В** *м.* и **ТЕРНОСЛИ'ВА** *ж. бот.* — кара җимеш.

**ТЕРПЕЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — түземлелек, сабырлылык, чыдамлылык.

**ТЕРПЕЛИ'ВЫЙ** — түземле, чыдамлы, сабыр; *терпеливый человек* — түземле кеше.

**ТЕРПЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. түземлек, сабырлык, чыдамлык; 2. түзү, түзеп тору, сабыр итү, чыдау. ◇ **Вывести кого-либо из терпения** — берәр кешене чыгырыннан чыгару.

**ТЕРПЕНТИ'Н** *м. мн.* нет, *спец.* — терпентин, чәер (скипидар, канифоль ясауга китә торган чыршы сагызы).

**ТЕРПЕНТИ'ННЫЙ** и **ТЕРПЕНТИ'НОВЫЙ** *спец.* — терпентин...-ы, чәер...-ы; *терпентиновое масло* — терпентин мае.

**ТЕРПЕ'ТЬ** *несов.* — 1. түзү, чыдау, түзеп тору, сабыр итү, чыдап тору; *терпеть боль* — авыртуга түзү; 2. очрау; *терпеть неудачу* — уңышсызлыкка очрау; 3. кичерү; *терпеть лишения* — кыенлыклар кичерү; 4. ярау, мөмкин булу, күтәрү, көтү; *дело не терпит отлагательства* — бу эшне кичектерергә ярамый. ◇ **Время терпит** — вакыт бар әле. **Не терпит возражений** — каршы әйткәнне яратмый. **Терпеть не могу** *кого-чего* — күрә алмыйм, җенем сөйми (берәр нәрсәне, берәр кешене). **Бумага всё терпит** *разг. ирон.* — кәгазьгә теләсә нәрсә язып була.

**ТЕРПЕ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *страд.* кичерелү; *при безработице терпятся всевозможные лишения* — эшсезлек вакытында (эш таба алмаганда) төрле кыенлыклар кичерелә; 2. *безл.* чыдап булу; *не терпится сказать* — чыдап булмый, әйтәсе килә; *терпи, покуда терпится* — чыдап булганчы чыда.

**ТЕРПИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. түземлелек, чыдамлылык, түзеп тора алу, чыдый алу, түзеп торырлык булу, чыдарлык булу; *терпимость этого поступка сомнительна* — бу эшнең түзеп торырлык эш булуы шикле, бу эшкә түзеп тора алу шикле; 2. сабырлык, салкын канлылык, юл куючанлык; *терпимость к чужим мнениям* — кеше фикерләренә карата сабырлык. ◇ **Дом терпимости** *офиц. устар. эвф.* — фәхешханә.

**ТЕРПИ'МЫЙ** *книж.* — 1. чыдарлык, чыдап торырлык, түзәрлек, түзеп торырлык; *терпимое явление* — чыдарлык күренеш; 2. түземле, сабыр; *терпимый человек* — түземле кеше, сабыр кеше.

**ТЕ'РПКИЙ** — 1. рәхәтсез, күңелсез, ачы; *терпкая жизнь* — рәхәтсез тормыш; 2. теш камаштыра торган, авыз бөрештерә торган; *терпкое яблоко* — теш камаштыра торган алма (яшел ачы алма).

**ТЕ'РПКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. рәхәтсезлек, күңелсезлек; 2. теш камаштыра торган булу, авыз бөрештерә торган булу.

**ТЕРПУ'Г** *м. спец.* — терпуг (игәү урынына кулланыла торган эре тешле корал).

**ТЕРРАКО'ТА** *ж. мн.* нет — терракота (1. яндырылган балчык; 2. *собир.* шуннан ясалган әйберләр).

**ТЕРРАКО'ТОВЫЙ** — терракота... (дан ясалган), яндырылган балчыктан ясалган; *терракотовые изделия* — яндырылган балчыктан ясалган әйберләр.

**ТЕРРАКО'ТЧИК** *м. спец.* — балчык яндыручы, терракота хәзерләүче (эшче).

**ТЕРРА'РИЙ** и **ТЕРРА'РИУМ** *м.* — террарий, террариум (бака, кәлтә кебек кечкенә җанварларны асрый торган бина).

**ТЕРРА'СА** *ж.* — терраса (1. өй кырыендагы зур балкон; 2. *геогр.* тау киртләче).

**ТЕРРИТОРИА'ЛЬНЫЙ** — территориаль, җирле, эчке; *территориальные войска* — территориаль гаскәрләр; *территориальные воды* — эчке сулар (дингезнең, океанның бер дәүләткә генә караган яр буе сулары).

**ТЕРРИТО'РИЯ** *ж.* — территория (билгеле бер чикләре булган пространство).

**ТЕРРО'Р** *м. мн.* нет — террор (политик дошманнарга карата физик көч куллану); *фашистский террор* — фашистлар терроры.

**ТЕРРОРИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. террорлау, террор белән куркыту; 2. куркыту, куркытып бетерү.

**ТЕРРОРИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — террорлану, террор белән куркытылу; куркытылу.

**ТЕРРОРИ'ЗМ** *м. мн.* нет — терроризм, террорчылык (террорчылык тактикасы, террорчылык политикасы).

**ТЕРРОРИ'СТ** *м.*, **ТЕРРОРИ'СТКА** *ж. полит.* — террорист, террорчы (террор эшенә катнашучы яки террор яклы кеше).

**ТЕРРОРИСТИ'ЧЕСКИЙ** — террор...-ы, террорчылык...-ы; *террористическая политика* — террорчылык политикасы.

**ТЕРРОРИ'СТСКИЙ** — террорист...-ы, террористлар...-ы; *террористская группа* — террористлар группасы.

**ТЕ'РСКИЙ** — Терек...-ы, Терек елгасы...-ы; *терские казаки* — Терек казаклары.

**ТЁРТЫЙ** — 1. ышкылган, уылган, кырып хәзерләнгән; *тёртый хрен* — кырып хәзерләнгән керән; 2. изеп ясалган; *тёртые краски* — изеп ясалган буяулар; 3. *перен. разг. фам.* күпне күргән, шомарган; *тёр-*

*тый человек* — шомарган кеше. ◇ **Тёртый калач** — к. калач.

**ТЕРЦЕ'Т** *м.*— терцет (1. *муз.* өч тавыш өчен язылган музыкаль әсәр; 2. *лит.* өч мисраглы шигырь, өч юллы шигырь строфасы).

**ТЕРЦИ'НА** *ж. лит.*— терцина (1. *только мн.* өч юллы строфалардан торган шигырь; 2. шундый шигырьнең аерым строфасы).

**ТЕ'РЦИЯ** *ж.*— 1. *муз.* терция (беренче һәм өченче гамма арасындагы интервал; 2. *тип.* 16 пунктлы шрифт; 3. *науч.* секундның алтмыштан бер өлеше).

**ТЁРЩИК** *м. спец* — куручы, изүче (эшче); *тёрщик красок* — буяу изүче.

**ТЕРЯ'ТЬ** *несов.*— 1. югалту, җую; *терять деньги* — акча югалту; 2. төшеп калу; *телега в пути несколько раз теряла колесо* — юлда арбаның тәгәрмәче берничә тапкыр төшеп калды; 3. югалту, аерылу, мәхрүм калу; *терять друга* — дустыннан аерылу, дустыннан мәхрүм калу; 4. кимү; *терять в весе* — авырлыгы кимү; 5. юкка әрәм итү, әрәм итү; *не хочу терять с тобой времени* — синең белән юкка вакыт әрәм итәсем килми; 6. зыян күрү, зарар күрү, югалту; *он на этом деле теряет уже вторую тысячу рублей* — бу эштә ул ике мең сум зыян күрә инде. ◇ **Терять терпение** — чыдар хәл(е) калмау. **Терять из виду** — күздән югалту. **Терять слух** — чукраклану, ишетми башлау. **Терять зрение**—сукыраю. **Терять зубы** — тешләр(е) төшү. **Терять надежду** — өмет(ен) өзү. **Терять в чьём-н. мнении** — берәр кеше каршында үзеңнең дәрәҗәңне төшерү. **Нечего терять** *разг.*— бернәрсә дә югалтмас (-сың һ. б.). **Терять голову** или **терять ум** — каушап калу, башын югалту, акылын югалту. **Терять почву под ногами** — таянычын югалту. **Терять силу** — көч(е) бетү, көчен югалту.

**ТЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *страд.* югалтылу, төшерелү, җуелу; 2. югалу; *вещи теряются* — әйберләр югала; *теряться в толпе* — кеше арасына кереп югалу; 3. югалып калу, аптырап калу; *теряться в догадках* — нәрсә икәнен белмичә аптырап калу.

**ТЁС** *м. мн.* нет, *собир.*— такта, түбәлек такта.

**ТЕСА'К** *м.*— 1. *плотн.* балта, юну балтасы; 2. *воен. истор.* кыска кылыч (сугыш коралы).

**ТЕСА'ЛЬЩИК** *м. спец.*— юнучы (эшче).

**ТЕСА'ТЬ** *несов.*— юну, юнып төшерү, юнып ясау; *тесать бревно* — бүрәнә юну. ◇ **Хоть кол на голове теши** — тискәре кеше, кире беткән кеше, үҗәт.

**ТЕСА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— юнылу, юнып төшерелү, юнып ясалу.

**ТЕСЁМКА** *ж.*— к. тесьма.

**ТЕСЁМОЧНИК** *м.*, **ТЕСЁМОЧНИЦА** *ж. спец.*— тасмачы (тасма тукучы).

**ТЕСЁМОЧНЫЙ** — 1. тасма ... -ы; *тесёмочное производство* — тасма производствосы; 2. тасмадан ясалган; *тесёмочные нашивки* — тасмадан ясалган нашивкалар.

**ТЕСЁМЧАТЫЙ** *спец.*— тасмага охшаган, тасма төсле, тасмасыман; *тесёмчатые глисты* — тасмасыман суалчаннар.

**ТЕСИ'НА** *ж. плотн.*— бер такта.

**ТЕСЛО'** *ср. плотн.*— аркылы балта (балта остасы коралы).

**ТЕСНИ'НА** *ж.*— тар аралык, тарлавык (ике тау арасындагы тар юл).

**ТЕСНИ'ТЬ** *несов.*— 1. кысу, тыгызлау; *теснить друг друга в толпе* — халык арасында бер-береңне кысу; *сапог теснит ногу* — итек аякны кыса; 2. кысрыклау; *теснить противника* — дошманны кысрыклау; 3. кысу, җәберләү; *отец перед смертью страшно теснил сына* — үләр алдыннан атасы улын бик җәберләде; 4. *безл.* кысу; *мне грудь теснит, не могу вздохнуть* — күкрәгем кыса, тын ала алмыйм; 5. *перен.* кысу; *горе теснит грудь* — кайгы күкрәкне кыса.

**ТЕСНИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. өелешеп тору, кысылышып тору; *тесниться у входа* — ишек төбендә кысылышып тору; 2. этколәшеп чыгарга (үтәргә) тырышу; *тесниться к выходу* — этколәшеп чыгарга тырышу; 3. *перен.* кайнау, кайнашу, сыймау; *теснятся думы* — фикерләр кайный.

**ТЕ'СНО** — 1. *нареч.* тыгыз, тыгыз рәвештә, бик нык; *эти вопросы тесно связаны друг с другом* — бу мәсьәләләр бер-берсе белән бик нык бәйләнгән; 2. *безл. в знач. сказ.* тыгыз, кысынкы; *в вагоне было тесно* — вагонда тыгыз иде. ◇ **Под мышкой тесно** — култык асты кыса (кием турында). **В груди стало тесно** — тыным кысыла башлады, күкрәгем кыса башлады.

**ТЕСНОТА'** *ж. мн.* нет — тыгызлык, кысынкылык; *они жили в тесноте* — алар бик кысынкылыкта яшиләр иде. ◇ **В тесноте, да не в обиде** — өең тар булса да, күңелең киң булсын.

**ТЕ'СНЫЙ** — 1. тыгыз, тар, кысынкы, кысан; *тесная комната* — кысынкы бүлмә; *тесная улица* — тар урам; *тесная обувь* — кысан аяк киеме; 2. *перен.* якын, нык, тыгыз; *тесная дружба* — якын дуслык; *тесная связь* — нык бәйләнеш; 3. *перен. разг.* авыр; *сам я стар, дела подошли тесные* (А. Островский) — үзем мин карт, эшләр авырга китте. ◇ **В тесном смысле слова** *книж.*— сүзнең туры мәгънәсендә, тар мәгънәсендә.

**ТЕСО'ВЫЙ** — такта(дан ясалган), такта(дан эшләнгән); *тесовые ворота* — такта капка; *тесовая крыша* — такта түбә.

**ТЕССИТУ'РА** *ж. мн.* нет, *муз.*— тесситура (музыкаль әсәр тавышларының музыка коралына яки берәр тавыш диапазонына җайланыш тәртибе).

**ТЕ'СТО** *ср. мн.* нет — 1. камыр; *кислое тесто* — ачы камыр; *пресное тесто* — төче камыр; 2. измә; *цементное тесто* — цемент измәсе.

**ТЕСТОДЕ'Л** *м. спец.*— камыр хәзерләүче, камыр изүче (икмәк заводында).

**ТЕСТОДЕ'ЛАТЕЛЬНЫЙ** *спец.*— камыр хәзерли торган, камыр изә (баса) торган;

*тестоделательная машина* — камыр хәзерли торган машина.

**ТЕСТОМЕ'С** *м. спец.* — камыр изүче (эшче).

**ТЕСТОМЕСИ'ЛКА** *ж. спец.*— камыр изгеч, камыр изә торган машина.

**ТЕСТОМЕСИ'ЛЬНЫЙ** *спец.*— камыр изә торган; *тестомесильная машина* — камыр изә торган машина.

**ТЕСТООБРА'ЗНЫЙ** — камырсыман; *тестообразная масса* — камырсыман масса.

**ТЕСТЬ** *м.*— каената, каенатай, бабай (иргә карата хатынның атасы).

**ТЕСЬМА'** *ж. мн.* нет — тасма; *подпоясаться тесьмою* — билне тасма белән бугып кую.

**ТЕТАНИ'Я** *ж. мн.* нет — тетания (күбрәк аяк-кулларда мускуллар тартышу авыруы).

**ТЕ'ТАНУС** *м. мн.* нет. *мед.*— к. столбняк.

**ТЕТ-А-ТЕ'Т** *м.*— 1. икәүдән икәү генә сөйләшү, икәүдән икәү генә очрашу; 2. *в знач. нареч.* икәүдән икәү генә.

**ТЁТЕНЬКА** *ж. просторечн.*— к. тётя.

**ТЕ'ТЕРЕВ** *м.*— көртлек, кыр тавыгы (кош). ◇ **Глухой тетерев** — 1. урман тавыгы; 2. *разг.* саңгырау кеше.

**ТЕТЕРЕВИ'НЫЙ** — көртлек ... -ы; *тетеревиный клюв* — көртлек томшыгы.

**ТЕТЁРКА, ТЕТЕ'РЬКА** *ж.*— 1. ана көртлек; 2. *только ед.* кыздырылган көртлек ите, көртлек итеннән пешерелгән куырдык.

**ТЕТЕ'РЯ** *ж. обл.* — тетерев. ◇ **Глухая тетеря** — саңгырау, колакбай, чукрак.

**ТЕТЁХА** *ж. просторечн. пренебр.*— алпавыт биясе (юаш һәм тупас хатын турында әйтелә).

**ТЕТИВА'** *ж.*— 1. (нык итеп тартылган) аркан, бау; 2. җәя җебе, кереш; 3. *спец.* баскыч тирәге.

**ТЁТКА** *ж.*— 1. апа (атаның яки ананың хатын-кыз туганы); 2. *просторечн.* апа (гомумән хатыннарга эндәшкәндә әйтелә). ◇ **Голод не тётка** (поговорка) — ачлык кардәшең түгел, нужа калач ашата.

**ТЕТРАГОНА'ЛЬНЫЙ** *мат.* — дүртпочмаклы.

**ТЕТРА'ДКА** *ж. разг.*— к. тетрадь.

**ТЕТРА'ДНЫЙ** — дәфтәр ... -ы; *тетрадная бумага* — дәфтәр кәгазе.

**ТЕТРА'ДЬ** *ж.*— дәфтәр; *общая тетрадь* — калын дәфтәр.

**ТЕТРАЛО'ГИЯ** *ж. лит.* — тетралогия (бер-беренә бәйле дүрт әсәрдән гыйбарәт булган роман).

**ТЕТРА'ЭДР** *м. мат.*— тетраэдр (һәр ягы өчпочмактан торган дүрткырлык, мәсәлән, пирамида).

**ТЁТУШКА** *ж. разг.*— к. тётка.

**ТЁТЯ** *ж. разг.*— 1. к. тётка; 2. *детск.* апа; 3. *фам. шутл.* таза юан хатын.

**ТЕ'ФТЕЛИ** *ед.* нет, *кулин.*— тефтели (иттән хәзерләнгән кечкенә кәтлитләрдән гыйбарәт ашамлык).

**ТЕХМИ'НИМУМ** *м.*—техминимум (производства эшли торган һәрбер кеше белергә тиеш булган техник белем).

**ТЕ'ХНИК** *м.*— техник (1. техникадан урта мәгълүматлы белгеч; 2. техника һәм техник фәннәр белгече).

**ТЕ'ХНИКА** *ж. мн.* нет — 1. техника; *передовая техника* — алдынгы техника; 2. техника (берәр эштә кулланыла торган алымнар); *техника шахматной игры* — шахмат уенының техникасы; *техника безопасности* — куркынычсызлык техникасы (производствода эшләүчеләрне хәвеф-хәтәрдән саклау чаралары); 3. техника, машиналар; *обилие техники в колхозах*— колхозларда техниканың (машиналарның) күплеге.

**ТЕ'ХНИКУМ** *м.*— техникум (урта техник уку йорты).

**ТЕХНИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет — техницизм (берәр эшнең техник ягы белән генә мавыгып, аның асылына зыян китерү).

**ТЕХНИ'ЧЕСКИЙ** —1. техник, техника...-ы; *технические науки* — техник фәннәр; *технический институт* — техника институты; 2. техник; *технические культуры* — техник культуралар (үсемлекләр); *технический редактор* — техник редактор. ◇ **Техническая система единиц** — берәмлекләрнең техник системасы (озынлык берәмлеге итеп метр, вакыт берәмлеге итеп секунд, авырлык берәмлеге итеп килограмм алынган берәмлекләр системасы). **Техническая скорость** — техник тизлек (берәр машинаның эшләгәндә ирешә ала торган максималь тизлеге). **Технический минимум** — к. техминимум.

**ТЕХНИ'ЧКА** *ж. разг.*— техничка (ярдәмче эштә эшләүче түбән квалификацияле эшче хатын-кыз).

**ТЕХНИ'ЧНЫЙ** — техникалы, техникага ия булган; *техничный боксёр* — техникалы боксёр.

**ТЕХНО'ЛОГ** *м.*— технолог, технология белгече.

**ТЕХНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** —технологик, технология ... -ы; *технологические испытания* — технологик сынаулар; *технологический институт* — технология институты.

**ТЕХНОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — технология (1. чималларны фабрикат итеп эшкәртү ысуллары турындагы фән; 2. шулай эшкәртү процесслары).

**ТЕХНОРУ'К** *т.*— технорук (техник җитәкче).

**ТЕХПЕРСОНА'Л** *м. мн.* нет — техник персонал, техперсонал (берәр заводта, фабрикада яки учреждениедә ярдәмче эштә эшләүче кешеләр).

**ТЕХПРОПАГА'НДА** *ж. мн.* нет — техпропаганда (техниканы һәм аның унышларын пропагандалау).

**ТЕХРЕ'Д** *м.*— техред, техник редактор.

**ТЕЧЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* агу, агым, агыш, барыш; *течение реки* — елганың агуы; *тёплое течение* — җылы агым; *течение дел* — эшләрнең барышы; 2. *перен.* агым; *политическое течение* — политик агым; *литературное течение* —әдәби агым.

◇ **В течение** — эчендә, дәвамында; *в течение одного дня* — бер көн эчендә. **Плыть по течению** *книж. перен.* — агым уңаена йөзү; җил кайсы якка булса, шул якка борылу (үзенә мөстәкыйль тормыш юлы таба алмыйча, башкаларга ияреп эш итү, яшәү). **Против течения** (идти, плыть, грести) *перен. книж.* — агымга каршы (бару, ишү, йөзү, күпчелеккә каршы бару). **С течением времени** — вакыт үтү белән.

**ТЕ'ЧКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — шылтыр (хайваннарда җенси теләк кузгалу, качу чоры).

**ТЕЧЬ** I *несов.* — 1. агу; *река течёт* — елга ага; *кровь течёт из раны* — ярадан кан ага; 2. *разг.* су үтү, агу, таму; *крыша течёт* — түбәдән су үтә; *ведро течёт* — чиләк ага; 3. үтү; *время быстро течёт* — вакыт тиз үтә; 4. агылу; *звуки текут* — авазлар агыла; *текла за ратью рать* — (Пушкин) — гаскәр артыннан гаскәр агыла иде.

**ТЕЧЬ** II *ж. мн.* нет — 1. керү, үтү, чыгу (су һ. б. сыекчалар); *в лодке открылась течь* — көймәгә су керә башлады (ярыктан, тишектән); 2. су үтә (керә) торган урын, тишек; *заделать течь* — тишекне (яки су үтә торган урынны) ямап кую (кадаклап кую, тыгып кую).

**ТЕ'ШИТЬ** *несов.* — юату, күңелен табу, көлдерү; *тешить ребят* — балаларны көлдерү.

**ТОРГОВА'ТЬ** *несов.*—1. сату итү, сәүдә итү; *торговать хлебом* — икмәк белән сату итү; 2. сату итү, ачык булу; *магазин торгует до 12 часов ночи* — магазин төнге 12 гә хәтле сату итә (ачык); 3. *перен.* акчага сату; *торговать совестью* — вөҗданын акчага сату; 4. *простореч.* сатулашу; *торговать коня* — ат сатулашу.

**ТОРГОВА'ТЬСЯ** *несов.*—1. сатулашу; 2. *простореч.* сатулашу, киреләнү, тартышу, бәхәсләшү; *не торгуйся, тебе придётся это сделать* — сатулашма, сиңа (барыбер) аны эшләргә туры килер.

**ТОРГО'ВЕЦ** *м.*— сәүдәгәр, сату итүче, сатучы.

**ТОРГО'ВКА** *ж.*— сәүдәгәр, сату итүче, сатучы (хатын-кыз).

**ТОРГО'ВЛИШКА** *ж. мн.* нет, *разг. уничижит.*— к. торговля.

**ТОРГО'ВЛЯ** *ж. мн.* нет — сәүдә, сату итү.

**ТОРГО'ВО-ПРОМЫ'ШЛЕННЫЙ** — сәүдә-промышленность...-ы; *торгово-промышленный банк* — сәүдә-промышленность банкысы.

**ТОРГО'ВЫЙ** — сәүдә...-ы; *торговый договор* — сәүдә договоры; *торговый флот* — сәүдә флоты; *торговая сеть* — сәүдә челтәре.

**ТОРГПРЕ'Д** *м.* (торговый представитель)— торгпред, сәүдә вәкиле.

**ТОРГПРЕ'ДСТВО** *ср.*— сәүдә вәкиллеге.

**ТОРЕАДО'Р** *м.*— тореадор (үгезләр белән сугышканда — үгезне чәнчеп үтерүче).

**ТОРЁНЫЙ** *обл.*— к. торный.

**ТОРЕ'Ц** *м.*— торец (1. урамга җәя торган алты кырлы агач бүкән; 2. *собир.* шундый бүкәннәр түшәлгән урам, юл; 3. бүрәнәнең, борысның һ. б. аркылы киселгән башы).

**ТОРЖЕ'СТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — тантаналылык; *празднество прошло с большой торжественностью* — бәйрәм бик зур тантаналылык белән үтте.

**ТОРЖЕ'СТВЕННЫЙ** — тантана...-ы, тантаналы; *торжественное заседание* — тантаналы утырыш.

**ТОРЖЕСТВО'** *ср.*— 1. *книжн.* тантана; *октябрьские торжества* — Октябрь бәйрәме тантаналары; 2. җиңү шатлыгы, өстенлек тойгысы; *на лице его отразилось торжество* — аның йөзендә шатлык балкыды; 3. җиңү, өстен чыгу.

**ТОРЖЕСТВОВА'ТЬ** *несов.*—1. шатлану, бәйрәм итү, тантана итү; *торжествовать*

*победу над врагом* — дошманны җиңү уңае белән бәйрәм итү; 2. җиңеп чыгу, җиңү, өстенлек алу, өстен чыгу; *торжествовать над врагом* — дошманны җиңү.

**ТО'РЖИЩЕ** *ср. устар.*—1. базар; 2. *поэт. ритор.* тормыш ыгы-зыгысы.

**ТО'РИ** *м. нескл. истор.*— тори (17—19 йөзләрдә Англиядә реакцион политик партия; 19 йөзнең уртасында консерваторлар партиясенә әйләнә).

**ТО'РИЙ** *м. мн.* нет, *хим.*— торий (химик элемент, металл).

**ТОРИ'ТЬ** *несов. обл.*— к. проторять.

**ТОРИ'ЦА** *ж. мн.* нет, *бот.*— кәҗә гөле, керпе үләне.

**ТОРИ'ЧНЫЙ** *бот.*— кәҗә гөле...-ы; керпе үләне...-ы; *торичное семя* — кәҗә гөле орлыгы.

**ТО'РКАТЬ** *несов. обл.*— к. толкать, дёргать.

**ТО'РКАТЬСЯ** *несов. обл.*— к. толкаться, стучаться.

**ТОРМА'ШКИ: вверх тормашки** или **вверх тормашками** —1. мәтәлеп (китү), баш аша (китү); 2. *перен.* бөтенләй тәртипсез рәвештә, асты-өскә (килү); *всё пошло вверх тормашками* — бөтенесе асты-өскә килде.

**ТО'РМОЗ** *м.*—1. *тех.* тормоз (машинаның хәрәкәтен акрынайту яки туктату аппараты); 2. *перен. книж.* тоткарлык, комачау, киртә (берәр эшне тоткарлап тора торган нәрсә); *главным тормозом в их работе является теснота помещения* — бинаның кысанлыгы аларның эшендә иң зур комачау булып тора.

**ТОРМОЗИ'ЛЬЩИК** *м. разг.*— тоткарлаучы, комачаулаучы, аяк чалучы, киртә куючы (берәр эшкә).

**ТОРМОЗИ'ТЬ** *несов.*—1. тормозлау (тормоз ярдәме белән механизмның хәрәкәтен акрынайту яки туктату); 2. *перен.* тоткарлау, комачаулау, аяк чалу, киртә кую (берәр эшкә).

**ТОРМОЗИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*—1. тормозлану, тормоз салыну; 2. тоткарлану, комачаулану, аяк чалыну, киртә куелу (берәр эшкә).

**ТОРМОЗНО'Й** *тех.*— тормоз...-ы; *тормозной кран* — тормоз краны.

**ТОРМОЗНУ'ТЬ** *сов. простореч.*— кинәт тормозлау, кинәт тормоз салу, кинәт туктату.

**ТОРМОШИ'ТЬ** *несов. разг.*—1. тарткалау, йолыккалау; *тормошить концы пояса* — билбауның очларын тарткалау; 2. *перен. фам.* йөдәтү, алҗыту; *ребята тормошат учителя вопросами* — балалар укытучыны сораулар биреп йөдәтәләр.

**ТОРМОШИ'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.*— тарткалану, йолыккалану.

**ТОРНА'ДО** *м. нескл.*— торнадо (АКШның үзәк һәм көньяк-көнчыгыш өлешләрендә еш була торган көчле давыл).

**ТО'РНЫЙ** —1. такыр, тигез; *торная тропка* — такыр сукмак; 2. *перен.* гадәттәге, тапталган; *торная дорога* — тапталган юл.

**ТОРОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет —1. *простореч.* юмартлык, киң күңеллелек; 2. *обл.* житезлек, тизлек, өлгерлек, булдыклылык.

**ТОРОВА'ТЫЙ** — 1. *простореч.* юмарт, киң күңелле; *не богат, да троват* — бай булмаса да, юмарт; 2. *обл.* житез, өлгер, булдыклы; *торовaт на деле* — эштә җитез.

**ТОРОКА'** *ед.* нет, *спец.*— ияр каешы (әйбер бәйләп кую өчен).

**ТОРОПИ'ТЬ** *несов.*— 1. ашыктыру; *торопить с окончанием работы* — эшне тизрәк бетерергә дип ашыктыру; 2. тизләтү, тизләштерү; *торопить события* — вакыйгаларны тизләштерү.

**ТОРОПИ'ТЬСЯ** *несов.*— ашыгу; *торопиться на поезд* — поездга ашыгу.

**ТО'РОПКИЙ** *обл.* — к. торопливый.

**ТОРОПЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — ашыгучанлык, сабырсызлык.

**ТОРОПЛИ'ВЫЙ** —1. ашыгучан, сабырсыз; *торопливый человек* — ашыгучан кеше; 2. ашыгыч; *торопливые шаги* — ашыгыч адымнар.

**ТОРОПЫ'ГА** *м.* и *ж. простореч. фам.*— ашыгучан кеше, ашык-пошык эшләүче кеше.

**ТОРО'С** *м.*— боз тавы, боз өеме (поляр диңгезләрдә аслы-өсле ябышып каткан боз өеме).

**ТОРОСИ'ТЬ** *несов. спец.*— боз таулары өю, боз өемнәре өю.

**ТОРОСИ'ТЬСЯ** *несов. спец.*— тау-тау булып бозлар өелү, боз таулары өелү.

**ТОРОЧИ'ТЬ** *несов.*— 1. *воен. охот.* ияргә бәйләп кую; ияргә бәйләү; 2. *порт. сапож.* эдепләү, кайма тоту (кием читенә берәр нәрсә тоту).

**ТОРОЧИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. ияргә бәйләп куелу; 2. эдепләнү, кайма тотылу (кием читенә берәр нәрсә тотылу).

**ТОРПЕ'ДА** *ж.*— торпеда (1. *воен. мор.* суда үзе бара торган мина; 2. сигарасыман өсте ачык автомобиль; 3. *зоол.* балык төре).

**ТОРПЕДИ'РОВАТЬ** *сов. воен. мор.*— торпеда ату, торпеда җибәрү, торпеда белән һөҗүм итү; *торпедировать неприятельское судно* — дошман судносына торпеда белән һөҗүм итү.

**ТОРПЕДИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. воен. мор.*— торпеда белән атакалану, торпеда белән һөҗүм ителү.

**ТОРПЕДИ'СТ** *м. воен. мор.*— торпедист, торпедачы (торпеда судносында хезмәт итүче гаскәри).

**ТОРПЕ'ДНЫЙ** — торпеда...-ы; торпедалы; *торпедный аппарат* — торпеда аппараты; *торпедный катер* — торпедалы катер.

**ТОРПЕ'ДО** *м. нескл. спец.*— к. торпеда 2.

**ТОРПЕДОМЕТА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— торпеда ату, торпеда җибәрү.

**ТОРПЕДОНО'СЕЦ** *м. воен. ав.* — торпедоносец (торпеда ташлый торган самолёт).

**ТОРС** *м.*— 1. торс, гәүдә; 2. торс (башы һәм кулы ватылып төшкән статуя гәүдәсе).

**ТОРТ** *м.*— торт (татлы ашамлык).

**ТО'РТОВЫЙ** — торт...-ы; *тортовое производство* — торт производствосы.

**ТОРФ** *м. мн.* нет — торф (ягулык, ашлама).

**ТОРФО'ЛЕУМ** *м.*— торфолеум (торфны пресслап ясаган төзү һәм изоляция материалы).

**ТОРФОРАЗРАБО'ТКИ** *ед.* нет — торф чыгару урыны.

**ТОРФОРЕ'З** *м. тех.*— торфорез, торф кискеч (торф кисә торган машина).

**ТОРФОСО'С** *м. тех.*—торф насосы, торф суыргыч.

**ТОРФЯНИ'К** *м.* — 1. торфлык, торфлы сазлык; 2. *спец.* торфчы, торф чыгаручы (эшче, белгеч).

**ТОРФЯНИ'СТЫЙ** *спец.* — торфлы; *торфянистая почва* — торфлы жир, торфлы туфрак.

**ТОРФЯНО'Й** — 1. торфлы; *торфяное болото* — торфлы сазлык; 2. торф...-ы; *торфяная промышленность* — торф промышленносте.

**ТОРЦ** *м.* — к. торец.

**ТОРЦЕВА'ТЬ** *несов. спец.*— бүкән түшәү, агач бүкәннәр түшәү; *торцевать мостовую*—урамга агач бүкәннәр түшәү.

**ТОРЦЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— агач бүкәннәр түшәлү.

**ТОРЦЕВО'Й, ТО'РЦЕВЫЙ** *спец.*—к. торцовый.

**ТОРЦО'ВКА** *ж. мн.* нет—1. *спец.* к. торцевать; 2. *разг. устар. (торцовая мостовая)* бүкән җәйгән юл, бүкән түшәлгән урам.

**ТОРЦО'ВЫЙ** —1. торец...-ы; 2. бүкән җәелгән, бүкән түшәлгән; *торцовая мостовая*—бүкән түшәлгән урам.

**ТОРЧА'ТЬ** *несов. разг. фам. неодобр.* — 1. чыгып тору, тырпаеп тору, калкып тору; *бревно торчит из воды*—судан бүрәнә чыгып тора; *вихры торчат*—чәчләре тырпаеп тора; 2. *перен. разг. неодобр.* (көннәр буе) китми тору, (көннәр буе) чыкмый тору, (көннәр буе) басып тору; *торчать на улице*—(көннәр буе) урамда басып тору.

**ТОРЧКО'М** *разг.*, **ТОРЧМЯ'** *нареч. обл.*— тырпаеп (тору); *усы торчком* — мыеклары тырпаеп тора.

**ТОРШО'Н** *м. мн.* нет, *спец.* — торшон (1. киже-мамык тукыма; 2. рәсем ясый торган кытыршы кәгазь).

**ТОРШОНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— кәгазьнең өстен кытыршылау.

**ТОСКА'** *ж. мн.* нет — 1. сагыну, сагыш; *тоска по родине* — туган илне сагыну; 2. *простореч. фам.* эч пошу, эчпошыргыч нәрсә; *эта книга — сплошная тоска* — бу китап — бик эчпошыргыч нәрсә.

**ТОСКЛИ'ВЫЙ** — 1. күңелсез, сагышлы; *тоскливая жизнь*—күңелсез тормыш; 2. эчпошыргыч, күңелсез; *тоскливая погода* — эчпошыргыч һава.

**ТОСКОВА'ТЬ** *несов.*— сагыну, сагышлану, пошыну, эч пошу; *тосковать по друзьям*— дусларны сагыну.

**ТОСТ** *м.* — тост (берәр кеше яки берәр нәрсә хөрмәтенә мәҗлестә речь сөйләп бокал күтәрү).

**ТОТ** *м.* (та *ж.*, то *ср.*)—1. шул, теге; ул; *в тот год*—шул елны, ул елны; *тот дом*— шул йорт; *по ту сторону* — теге якта; *в тот день было холодно* — ул көнне суык иде; 2. башка, бүтән, икенче; *сел не в тот вагон*—башка вагонга утырды; *он стал не тот* — ул хәзер башка иде. ◇ **Не в том дело** — эш анда түгел. **В том-то и дело** — бөтен хикмәт тә шунда. **Дело в том, что...**— эш шунда ки... **Вследствие того, что...**— ... сәбәпле. **По мере того, как...** — ...-ган саен; *по мере того, как мешки наполнялись, их увозили* — капчыклар тулган саен, аларны алып китә тордылар. **После того, как...** — ...-ганнан соң. **Перед тем, как...**— ...-ыр алдыннан; *перед тем, как лечь* — ятыр алдыннан. **Несмотря на то, что...**—...-га карамастан; *несмотря на то, что было поздно* — соң булуга карамастан. **С тем, чтобы...**—...өчен; *с тем, чтобы не опоздать* — соңга калмас өчен. **Для того, чтобы...** — ...-р өчен; *для того, чтобы сделать это, нужно время*—моны эшләр өчен вакыт кирәк. **При всём том**—шуның белән бергә; *при всём том надо понимать, что мы не одни*—шуның белән бергә, без ялгыз түгеллекне истә тотарга кирәк. **Кроме того**—шуның өстенә, өстәвенә; *кроме того он был глуп* — өстәвенә ул ангыра иде. **К тому же** — җитмәсә тагын, өстәвенә; *к тому же он очень хорошо пел*—өстәвенә ул бик яхшы җырлый иде. **Тем не менее**— шулай булуга карамастан. **Тем паче** — бигрәк тә. **Как бы то ни было** — һәрхәлдә, ничек кенә булса да. **И тому подобное** — һәм башка шундыйлар. **Всё не то** — юк, болар берсе дә батмый. **Тот или иной**—берәр, берәр төрле, нинди дә булса берәр; *тот или иной результат* — нинди дә булса берәр нәтиҗә. **До того, что...**—...-ганчы, шул кадәр; *кричал до того, что охрип*—тамагы карлыкканчы кычкырган. **И без того** — ансыз да, аннан башка да; *сегодняшний день у меня и без того пропал* — ансыз да бүгенге көнем әрәм булды. **(Да) и то сказать** *разг.*—дөрестән дә, чыннан да. **Не без того**—бераз бар; ансыз түгел; *опять пьян?— не без того* — тагы исерек? — бераз бар. **Не то, чтобы...**—...диярлек түгел, ... дип әйтерлек түгел; *ужли с ума сошёл? — не то чтобы совсем* (Грибоедов)—чынлап та акылыннан язганмы? — бөтенләй үк диярлек түгел. **Ни с того, ни с сего** *разг.* — тик торганда, бернинди сәбәпсез; *ни с того, ни с сего рассердился и ушёл* — тик торганда ачуланды да чыгып китте. **Ни то, ни сё** *разг. пренебр.* — ни аллага, ни муллага. **Того и гляди** — көт тә тор. **То ли дело** *разг.*—бөтенләй башка (эш башкача). **Тому назад**—моннан элек; *год тому назад*—моннан бер ел элек. **То да сё**—тегесе-монысы, анысы-монысы.

**ТОТАЛИЗА'ТОР** *м.* — тотализатор (1. ат чабышында кайсы атка күпме акча куелганлыкны исәпкә алу приборы; 2. ат чабышларында отыш уены).

**ТОТАЛИТА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— тоталитарлык.

**ТОТАЛИТА'РНЫЙ** — тоталитар; фашистик, фашистлар...-ы; *тоталитарный режим* — тоталитар режим, фашистлар режимы.

**ТОТА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — тоталь, гомуми (барысын да эченә ала торган); *тотальная война*—тоталь сугыш.

**ТОТЕ'М** *м. этнол.* — тотем (1. борынгы халыкларда берәр семьяның яки кабиләнең табына һәм олылый торган хайваны, үсемлеге яки әйбере; 2. шул хайванның яки әйбернең сурәте).

**ТОТЕМИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *этнол.* — тотемизм (1. борынгы дәверләрдә тотемнарга табыну; 2. шундый культ булган борынгы җәмгыятьнең иҗтимагый төзелеше).

**ТОТЕМИСТИ'ЧЕСКИЙ** — тотемизм ... -ы; тотемистик; *тотемистическое общество*— тотемистик җәмгыять.

**ТО'-ТО** *частица простореч.* — 1. шулай шул; *вот то-то все вы гордецы!* — менә шулай шул, сез барыгыз да тәкәббер! 2. менә ни өчен, шуның өчен, шуңа күрә, әйтәм; *он, оказывается, уезжал, то-то я всё не заставал его*—ул китеп барган икән, әйтәм, мин аны бер дә очрата алмый идем; 3. кара аны, белеп тор; *то-то же, смотри* — кара син аны, белеп тор. ◇ **Вот то-то и оно** — менә шул-шул.

**ТОТО'ШКА** *ж. мн.* нет, *просторечфам.*—к. тотализатор 2.

**ТО'ТЧАС** *нареч.* — шунда ук, хәзер үк, шул чакта ук, шул минутта ук; *тотчас приду*—шул минутта ук килермен.

**ТОЧЁНЫЙ** —1. кайралган, чарланган, үткерләнгән; *точёный нож*—үткерләнгән пычак; 2. кырылган, кырып ясалган; *точёные изделия*—кырып ясалган әйберләр; 3. *перен.* коеп куйгандай, коеп куйган кебек (матур); *точёный нос*—коеп куйган кебек матур борын.

**ТО'ЧЕЧКА** *ж. разг.* — к. точка.

**ТО'ЧЕЧНЫЙ** — төртеп-төртеп ясалган нокталардан ясалган, төрткеләрдән ясалган; *точечный узор* — төрткеләрдән ясалган бизәк.

**ТОЧИ'ЛКА** *ж.* — беләү, кайрак.

**ТОЧИ'ЛО** *ср. спец.* — чар.

**ТОЧИ'ЛЬНАЯ** *ж. спец.*—кайрау урыны.

**ТОЧИ'ЛЬНЫЙ** — кайрый торган, үткерли торган; *точильный камень*—кайрый торган таш.

**ТОЧИ'ЛЬЩИК** *м.*, **ТОЧИ'ЛЬЩИЦА** *ж.* — кайраучы.

**ТОЧИ'ТЬ** I *несов.*—1. кайрау, чарлау, үткерләү; *точить нож* — пычак үткерләү; 2. кыру, кырып ясау; *точить шахматные фигуры* — кырып шахмат фигуралары ясау.

**ТОЧИ'ТЬ** II *несов.* —1. тишү, кисү; *моль точит сукно* — көя суконны кисә; 2. ашау, тишү; *червь точит дерево* — корт агачны ашый; *вода точит камень*—су ташны тишә; 3. *перен.* киптерү, саргайту; *горе его точит*—кайгы саргайта аны; 4. *перен. (расточать)* әрәм-шәрәм итү. ◇ **Точить зубы** — к. зуб. **Точить лясы** *разг.*—к. лясы. **Точить нож или меч** *ритор.* — сугышка хәзерләнү.

**ТОЧИ'ТЬ** III *несов. книж. устар.*— агызу, саркыту; *точить слёзы* — яшь агызу (елау).

**ТОЧИ'ТЬСЯ** I *несов. страд.*—1. үткерләнү, кайралу, чарлану; 2. кырылу, кырып ясалу; 3. ашалу, киселү.

**ТОЧИ'ТЬСЯ** II *несов. книж. устар.* — таму, агу, сарку; *по капле кровь точилася моя* (Лермонтов) — минем каным тамчылап тама иде.

**ТО'ЧКА** I *ж.* — 1. бөрчек; *ситец в красных точках*—кызыл бөрчекле ситсы; 2. нокта, төртке; *после точки слова пишутся с большой буквы*—ноктадан соң сүзләр баш хәрефтән языла; *точка кипения (физ.)*—кайнау ноктасы; 3. урын, җир, пункт; *самая высокая точка горы*—тауның иң биек урыны; *торговая точка* — сәүдә пункты, сәүдә итү урыны (магазин, ларёк һ. б.); 4. *перен. в знач. межд.* тәмам, бетте, вәссәлам; *ещё полчаса поработаю — и точка*—тагы ярты сәгать эшлим дә — вәссәлам! ◇ **На мёртвой точке** — бер урында, үзгәрешсез. **В самую точку** (попасть) *разг.*— өстенә сугу, өстенә басу, нәкъ өстенә басу. **До точки довести**— актык чиккә җиткерү. **Ставить точку** — эшне бетерү, тәмамлау. **Ставить точки на и** или **над и** —1. үзеннән-үзе аңлашылып торган нәрсәне аңлату; 2. исбатлап бетерү, иң кирәген әйтеп бирү; 3. эшне азагына җиткерү. **Точка в точку** *разг. фам.* — хәрефкә-хәреф, ноктага-нокта; *переведено всё точка в точку* — бөтенесе хәрефкә-хәреф тәрҗемә ителгән. **Точка зрения**—караш. **Точка с запятой** — нокталы өтер.

**ТО'ЧКА** II *ж. мн.* нет — к. точить I.

**ТОЧНЁХОНЬКО** *нареч. просторeч.* — 1. бик төгәл, бик дөрес; *высчитать точнёхонько* — бик төгәл исәпләп чыгару; 2. к. точно 4.

**ТО'ЧНО** *нареч.* — 1. төгәл, дөрес, анык; *она всё делала точно и ловко* — ул бар эшне дөрес һәм оста эшли иде; *точно исполнить поручение* — тапшырылган эшне төгәл үтәү; *точно переписать что-н.* — берәр нәрсәне дөрес итеп күчереп алу; 2. нәкъ; *точно такая же книга* — нәкъ шундый ук китап; 3. *устар.* әйе, дөрес, шулай; *точно, я здесь был* — әйе, мин биредә булдым; 4. *ввод. сл. устар.* чыннан да, дөрестән дә; *она, точно, красива* — ул чыннан да матур; 5. *союз* гүя, әйтерсең лә ..., ... -дай, кебек, шикелле; *кричит, точно сумасшедший* — акылдан язган кебек кычкыра.

**ТО'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. төгәллек; *точность веса* — үлчәүнең төгәллеге; 2. аныклык, төгәл булу, дөреслек; *точность перевода*—тәрҗемәнең төгәл булуы. ◇ **В точности** — төгәл итеп.

**ТО'ЧНЫЙ**—1. төгәл, дөрес, анык; *точные приборы* — төгәл приборлар; *точный перевод* — төгәл тәрҗемә; 2. җыйнак, ыктымат; *точный человек* — җыйнак кеше. ◇ **Точные науки**—төгәл фәннәр (математикага нигезләнгән фәннәр). **Вот его точные слова** — менә аның нәкъ үз сүзләре.

**ТОЧЬ:** **точь-в-точь** *разг.* — сүзгә сүз, тәңгәл, нәкъ менә, нәкъ үзе, нәкъ үзе кебек итеп, суйган да каплаган, койган да куйган; *пересказать что-н. точь-в-точь* — берәр нәрсәне сүзгә сүз (яңадан) сөйләп бирү; *мальчик точь-в-точь отец* — малай нәкъ әтисе — койган да куйган.

**ТОШНЁХОНЬКО** *в знач. сказ. простореч.* — үземне үзем кая куярга белмим, косасым килә, авыр, күңелсез; *не говори... и без тебя тошнёхонько* (А. Островский) — сөйләмә... синнән башка да үземне кая куярга белмим.

**ТОШНИ'ТЬ** *несов. безл.* — 1. укшыту, күңел болгану, косасы килү; *меня тошнит* — минем косасы килә; 2. *перен.* чиркандыру, җирәндерү, косасы килү; *тошнит от твоих анекдотов* — синең анекдотларыңнан косасы килә.

**ТО'ШНО** *безл., в знач. сказ.* — 1. *устар. обл.* күңел болгана, косасы килә; 2. *перен.* күңелсез, начар, авыр, кыен; *как бывает жить ни тошно, а умирать ещё тошней* (Крылов) — тормыш никадәр генә күңелсез булмасын, үлем аннан да начаррак; 3. *перен.* чирканыч, җирәнгеч, күңел болгаткыч; *тошно смотреть на его безделье и пошлость* — аның эшсезлегенә һәм әшәкелегенә карап торуы чирканыч.

**ТОШНОТА'** *ж.* — күңел болгану, косасы килү, укшу.

**ТОШНОТВО'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. косасыны китерүчәнлек, күңел болгатучанлык; 2. чирканычлык, җирәнгечлек.

**ТОШНОТВО'РНЫЙ** — 1. күңел болгаткыч, күңел болгата торган, косасыны китергеч, косасыны китерә торган; *тошнотворный запах* — косасыны китерә торган ис; 2. *перен. разг.* җирәнгеч, чирканыч, күңел болгаткыч; *тошнотворное зрелище* — җирәнгеч күренеш.

**ТОШНО'ТНЫЙ** — 1. *мед.* күңел болгану...-ы; косасы килү...-ы, укшу...-ы; *тошнотные явления* — косасы килү билгеләре; 2. к. тошнотворный 2.

**ТО'ШНЫЙ** — 1. әчпошыргыч, йөдәткеч, күңел кайтаргыч; *тошный человек* — күңел кайтаргыч кеше; 2. к. тошнотворный.

**ТОЩА'ТЬ** *несов. разг.* — 1. ябыгу, арыклану; *ребёнок тощает* — бала ябыга; 2. *перен.* бушау, саегу; *карман тощает* — кесә саега (акча кими).

**ТО'ЩИЙ** — 1. ябык, арык; *тощее лицо* — ябык чырай; *тощая кляча* — арык ат; 2. *разг.* ач; *на тощий желудок* — ач карынга; 3. сай, буш; *тощий карман* — сай кесә, буш кесә; 4. ябык, уңдырышсыз, уңыш бирми торган; *тощая почва* — уңыш бирми торган җир.

**ТОЩИ'ЩА** *ж. мн.* нет, *разг. фам.* — к. тоска.

**ТПРУ** *частица* — тррр (ат туктату ымлыгы). ◇ **Ни тпру, ни ну** *простореч. шутл.* — бер эш тә чыкмый, эш урыныннан да кузгалмый, ни алга, ни артка китми.

**ТРАВА'** *ж.* — үлән; *сорная трава* — чүп үлән. ◇ **Трава травой** *разг.* — үлән кебек, бер тәме дә юк. **Травой поросло** — күптән булып онытылган. **Хоть трава не расти** *разг.* — җәһәннәмгә китмиме шунда; ике ятып бер төшенә дә керми; ни булса да барыбер. **Трава богородская** — чабыр үләне.

**ТРАВЕНЕ'ТЬ** *несов.* — к. травянеть.

**ТРА'ВЕРС** *м.* — траверс (1. *воен.* окопта һәм ныгытмаларда флангтан ачылган уттан саклану өчен балчык өеме; 2. *мор.* судноның алган курсына карата перпендикуляр юнәлеш; 3. *тех.* елганың ярларын саклау һәм агу юлын үзгәртү өчен махсус дамба; 4. *спорт.* атның ян белән чабуы; 5. *тех.* к. траверса).

**ТРА'ВЕРСА** *ж. тех.* — траверса (машинаның детальләре беркетелә торган өрлек).

**ТРАВЕРТИ'Н** *м. мн.* нет — травертин (бергә укмашып каткан тау токымнары — төзү материалы итеп кулланыла).

**ТРАВЕСТИ'** *ср. нескл.* — травести (1. *театр.* хатын-кызлар уйный торган ирләр роле яки ирләр уйный торган хатын-кызлар роле; 2. *лит.* житди әдәби әсәрне комик әсәргә әйләндерү).

**ТРАВИ'ЛЬНЫЙ** *спец.* — агулап үтерү...-ы; *травильные работы* — агулап үтерү эшләре (мәсәлән, тычканнарны).

**ТРАВИ'ЛЬЩИК** *м. спец.* — травильщик (химик юллар белән тапларны бетерүче һәм металларны чистартучы эшче).

**ТРАВИ'НА** *ж. разг.* — үлән сабагы.

**ТРАВИ'НКА** *ж. разг.* — кечкенә бер үлән сабагы, бер бөртек үлән.

**ТРАВИ'ТЬ** I *несов.* — 1. агулап үтерү; *травить мышей* — тычканнарны агулап үтерү; 2. агулау; *травить себя алкоголем* — үзенне аракы белән агулау; 3. *перен.* агулау; *травить сознание религией* — аңны дин белән агулау; 4. таптату, таптау; *скот травит посевы* — терлекләр чәчелгән игеннәрне таптыйлар; 5. *обл.* малга ашату, мал азыгына тоту; *мы солому травим, а не бережём* — без саламны сакламыйбыз, малга ашатабыз; 6. *простореч.* тоту, әрәм итү, исраф итү; *травить деньги на пустяки* — акчаны юк-бар нәрсәгә әрәм итү; 7. *спец.* ашату, бетерү; *травить пятна* — тапларны бетерү (химик юллар белән); 8. *спец.* (химик чаралар белән) ашатып рәсем төшерү; *травить медную доску* — бакыр тактага ашатып рәсем төшерү; 9. өстерү, эт белән куу; *травить лису* — төлкене эт белән куу; 10. *неодобр.* каныгу, яла ягу, эзәрләү, юри бәйләнеп интектерү.

**ТРАВИ'ТЬ** II *несов. мор.* — бушата төшү, җибәрә төшү, акрынлап бушату, акрынлап җибәрә төшү (суднолар бәйли торган бауны, арканны).

**ТРАВИ'ТЬСЯ** I *несов. разг.* — 1. агу эчү; *он с горя хочет травиться* — ул кайгысыннан агу эчәргә тели; 2. *страд.* ашатылу, бетерелү (химик юллар белән, мәсәлән, тап); 3. *страд.* рәсем төшерелү (химик юллар белән металлга); 4. *страд.* яла ягылу, эзәрләнү, юри бәйләнеп интектерелү.

**ТРАВИ'ТЬСЯ** II *несов. страд. мор.* — акрынлап бушатылу, акрынлап җибәрелү.

**ТРА'ВЛЕНЫЙ** — 1. химик чаралар белән ашатылган, химик чаралар белән бетерел-

гән; химик чаралар белән ясалган, химик чаралар белән төшерелгән; *травленый узор* — химик чаралар белән төшерелгән бизәк; 2. *охот.* эт белән куылган; *травленый зверь* — эт белән куылган җәнлек. ◇ **Травленый зверь** (волк, лиса и т. д.) *перен.* — карт төлке, күпне күргән кеше.

**ТРА'ВЛЯ** *ж. мн.* нет — к. травить 1 в 9 и 10 знач.

**ТРА'ВМА** *ж. мед.* — травма, яра, җәрәхәт; имгәнү; *травма от осколка* — осколок җәрәхәте. ◇ **Психическая травма** *мед.* — психик травма.

**ТРАВМАТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — травма...-ы, травматизм ...-ы, травматик; *травматическая лихорадка* — травматик бизгәк.

**ТРАВМОТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — травмотология...-ы; *травмотологический кабинет* — травмотология кабинеты.

**ТРАВМОТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — травмотология (хирургиянең травмаларны өйрәнә торган бүлеге).

**ТРА'ВНИК** *м.* — 1. *разг.* төнәтелгән үлән суы; *выпить рюмку травнику* — бер рюмка төнәтелгән үлән суы эчү; 2. *устар.* үләннәр җыелмасы, гербарий; 3. *обл.* үләнлек, чирәмлек, яхшы болын; 4. *истор. лит.* (борынгы Россиядә) тыиб китабы; 5. үләннәр белән дәвалаучы.

**ТРАВНИ'СТЫЙ** *разг.* — үләнле, үлән баскан, үлән каплаган; *травнистые зелёные дороги* — үлән каплаган яшел юллар.

**ТРАВОПО'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — басуга үлән чәчү системасы.

**ТРАВОПО'ЛЬНЫЙ** — (туфракның уңдырышын яхшырту өчен) үлән чәчүгә нигезләнгән, үлән чәчә торган; *травопольный севооборот* — үлән чәчүгә нигезләнгән чәчү әйләнеше.

**ТРАВОСЕ'ЯНИЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х.* — үлән чәчү.

**ТРАВОСМЕ'СЬ** *ж. с.-х.* — үлән катнашмасы.

**ТРАВОСТО'Й** *м. мн.* нет, *с.-х.* — үлән торышы.

**ТРАВОЯ'ДНЫЙ** *зоол.* — үсемлек белән туенучы; үлән ашаучы; *травоядные животные* — үсемлек белән туенучы хайваннар.

**ТРА'ВЧАТЫЙ** *старин.* — 1. үләнсыман, үләнгә охшашлы; *травчатый узор* — үләнсыман бизәк; 2. үләнсыман бизәк төшерелгән (мәсәлән, материя); 3. (гомумән) бизәкле.

**ТРА'ВЩИК** *м.* — 1. к. травильщик; 2. бизәкләүче, бизәк төшерүче.

**ТРАВЯНЕ'ТЬ** *несов. спец.* — үлән басу, үлән белән каплану.

**ТРАВЯНИ'СТЫЙ** — 1. к. травяной; 2. куе үләнле, куе үлән үскән; *травянистый луг* — куе үләнле болын; 3. *разг.* тәмсез, үлән тәме килгән; *травянистые щи* — үлән тәме килгән щи.

**ТРАВЯ'НКА** *ж.* — 1. *спец.* үләннән ясалган буяу; 2. *бот.* кыр канәфере; 3. *обл.* (ашарга ярамый торган) кабак.

**ТРАВЯНО'Й** — 1. үлән...-ы; *травяной запах* — үлән исе; *травяные поля* — үлән басулары; 2. үләннән ясалган, үлән...-ы; *травяная настойка* — үлән төнәтмәсе.

**ТРАГЕДИ'ЙНЫЙ** *лит. театр.* — трагедия...-ы; *трагедийный стиль* — трагедия стиле.

**ТРАГЕ'ДИЯ** *ж.* — трагедия (1. драма әсәренең көчле көрәш күренешләрен эченә алган төре; трагедия гадәттә геройның һәлакәте белән тәмамлана; 2. *перен.* фаҗига, тормышта зур бәхетсезлек).

**ТРАГИ'ЗМ** *м. мн.* нет — трагизм (1. *лит.* әдәби әсәрдә трагик элемент; 2. котылгысыз авыр хәл, фаҗигале хәл).

**ТРА'ГИК** *м.* — трагик (1. трагик рольләрне башкаручы артист; 2. трагедия әсәрләре язучы).

**ТРАГИКОМЕ'ДИЯ** *ж. лит.* — трагикомедия (1. трагедия һәм комедия элементларын эченә алган әсәр; 2. *перен. разг.* кайгылы һәм шуның белән бергә көлке вакыйга, хәл).

**ТРАГИКОМИ'ЧЕСКИЙ** — трагикомик, көлке аралаш фаҗигале; *трагикомический случай* — трагикомик вакыйга.

**ТРАГИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *лит. театр.* трагик...; трагедия...-ы; *трагический стиль* — трагедия стиле; 2. *театр.* трагик...; трагик рольләрне башкаручы; *трагический актёр* — трагик рольләрне башкаручы артист; 3. *книж.* фаҗигале, дәһшәтле; *трагический случай* — фаҗигале вакыйга; 4. *разг. шутл.* авыр.

**ТРАГИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — фаҗигалелек, дәһшәтлелек.

**ТРАГИ'ЧНЫЙ** — к. трагический 3, 4.

**ТРАДИЦИО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — традицияле булу, традициялелек (электән килгән гадәткә нигезләнгәнлек).

**ТРАДИЦИО'ННЫЙ** — 1. традицион, традициягә кергән, традиция булып киткән, гадәт булып киткән; *традиционный праздник* — гадәт булып киткән бәйрәм; 2. гореф-гадәтләрне саклаучы, гореф-гадәтләр буенча эш итүче; 3. искергән, оригинальлеген югалткан.

**ТРАДИ'ЦИЯ** *ж.* — 1. традиция (бер буыннан икенче буынга күчкән идея, караш, эш итү рәвеше); *революционные традиции пролетариата* — пролетариатның революцион традицияләре; 2. традиция, гореф-гадәт; *борьба с отжившими традициями* — искелән калган гореф-гадәтләр белән көрәш.

**ТРАЕКТО'РИЯ** *ж.* — траектория (1. *мат. физ.* берәр җисемнең яки ноктаның хәрәкәт юлы; 2. *воен.* очып барган пуляның яки снарядның кәкре сызыгы).

**ТРА'ЙЛЕР** *м. тех.* — трайлер (авыр йөк ташый торган өсте ачык тәбәнәк платформа-арба).

**ТРАКТ** *м.* — 1. тракт, юл, олы юл; 2. *спец.* маршрут, юнәлеш. ◇ **Желудочно-кишечный тракт** *анат.* — ашказаны-эчәкләр тракты (эш сеңдерү системасы). **Прямым трактом** *простореч. устар.* — туры юл белән, туп-туры, турыдан-туры.

**ТРАКТА'Т** *м.* — трактат (1. *книж.* аерым

мәсьәләне тикшереп язган гыйльми әсәр; 2. *дипл.* халыкара договор).

**ТРАКТИ'Р** *м. устар.* — трактир (электә — ашханәсе булган гостиница, соңрак — әрзан бәяле ресторан).

**ТРАКТИ'РНЫЙ** — 1. *устар.* трактир...-ы; *трактирный слуга* — трактир хезмәтчесе; 2. *простореч. презрит.* тупас, дорфа, кабакчылар...-ы; кабак...-ы; *трактирные нравы* — кабакчылар гадәте.

**ТРАКТИ'РЩИК** *м.*, **ТРАКТИ'РЩИЦА** *ж. устар.* — трактирчы, трактир тотучы, трактир хуҗасы.

**ТРАКТОВА'ТЬ** *несов.* — 1. фикер йөртү (гыйльми темага); *трактовать о серьёзных вопросах* — җитди мәсьәләләр турында фикер йөртү; 2. аңлату, бәя бирү, карашны әйтү; *актёр интересно трактует эту роль* — актёр бу рольне кызык аңлата.

**ТРАКТОВА'ТЬСЯ** *несов.* — фикер йөртелү, караш әйтелү, аңлатылу.

**ТРАКТО'ВКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. трактовать; 2. (*понимание, толкование*) аңлау, төшенү.

**ТРА'КТОР** *м.* — трактор.

**ТРАКТОРИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — тракторлаштыру.

**ТРАКТОРИ'СТ** *м.*, **ТРАКТОРИ'СТКА** *ж.* — тракторист, трактористка, тракторчы.

**ТРА'КТОРНЫЙ** — трактор...-ы; *тракторное производство* — трактор җитештерү.

**ТРАКТОРОСТРОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — тракторлар төзү, трактор эшләп чыгару.

**ТРАКТОРОСТРОИ'ТЕЛЬНЫЙ** — тракторлар эшләп чыгара торган, тракторлар төзи торган; *тракторостроительный завод* — тракторлар эшләп чыгара торган завод.

**ТРАЛ** *м.* — трал (1. *спец.* судноДан торып балык тоту өчен эшләнгән ятьмә; *рыболовный трал* — балык тоту тралы; 2. *воен. мор.* мина аулагыч; *минный трал* — мина аулагыч трал; 3. *мор.* су төбен тикшерү һәм су төбе хайваннарын аулау коралы).

**ТРА'ЛЕР** (тра́улер) *м. спец.* — к. тральщик 1.

**ТРА'ЛИТЬ** *несов. спец.* — 1. *спец.* траллау, трал белән балык тоту; 2. *воен. мор.* трал белән мина тоту; 3. *мор.* трал белән диңгез төбен тикшерү.

**ТРАЛМЕ'ЙСТЕР** *м. спец.* — трал остасы, тралмейстер (трал белән балык тотуда җитәкчелек итүче).

**ТРА'ЛОВЫЙ** — 1. *спец. воен. мор.* траллы, трал белән җиһазландырылган; трал белән кораллаНдырылган; *траловая флотилия* — трал белән кораллаНдырылган флотилия; 2. трал белән...; *траловый лов рыбы* — трал белән балык тоту.

**ТРА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — тральщик (1. трал белән җиһазландырылган балык тоту судносы; 2. *воен. мор.* су асты миналарын аулый торган хәрби судно).

**ТРАМБОВА'ТЬ** *несов.* — төеп тигезләү; тантап тигезләү.

**ТРАМБОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — төеп тигезләнү, тапталып тигезләнү.

**ТРАМБО'ВКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. трамбовать; 2. *спец.* трамбовка, төйгеч.

**ТРАМБО'ВЩИК** *ж. спец.* — трамбовщик (берәр нәрсәне таптатып тигезләүче).

**ТРАМВА'Й** *м.* — трамвай. ◇ **Речной трамвай** — елга трамвае, су трамвае (пассажирлар йөртү өчен кечкенә пароход).

**ТРАМВА'ЙНЫЙ** — трамвайлар...-ы; трамвай...-ы; *трамвайный вагон* — трамвай вагоны.

**ТРАМВА'ЙЩИК** *м.* — трамвайчы (трамвайда эшләүче).

**ТРАМПЛИ'Н** *м.* — трамплин (1. *спорт.* сикерү басмасы; 2. *перен.* таяныч, берәр эш эшләгәндә таяныч, башлангыч пункт булып тора торган нәрсә).

**ТРА'НЕЦ** *м. мор.* — транец (судноның койрык борысы).

**ТРАНЖИ'Р** *м.*, **ТРАНЖИ'РА** *м.* и *ж. разг.* — (мал, акча) туздыручы, исраф итүче.

**ТРАНЖИ'РИТЬ** *несов. разг.* — (мал, акча) туздыру, исраф итү.

**ТРАНЖИ'РИТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. (мал, акча) туздыру; әрәм итү; 2. *страд.* (акча) туздырылу, исраф ителү.

**ТРАНЖИ'РСТВО** *ср. разг.* — к. транжирить.

**ТРАНЗИ'Т** *м.* — транзит (1. *только ед.* бер дәүләттән икенче дәүләткә арадагы өченче дәүләт аркылы товар йөртү; *беспошлинный транзит* — пошлинасыз транзит; 2. арадагы пунктларда бушатмыйча бер җирдән икенче җиргә товар ташу; *послать грузы транзитом* — йөкләрне транзит белән җибәрү; 3. *астр. устар.* күк яктыртнычларының иңиндидер яссылык, күбесенчә берәр меридиан аша үтүе; 4. *устар. астр.* шундый үтүне күзәтә торган корал).

**ТРАНЗИ'ТНЫЙ** — 1. транзит...; *транзитные страны* — транзит илләр; 2. транзит..., транзит белән җибәрелә торган; *транзитный поезд* — транзит поезд; *транзитный товар* — транзит белән җибәрелә торган товар.

**ТРАНС** I *м. мн.* нет, *книж.* — транс (гипноз вакытында яки кеше кызып киткән вакытта нервларның бик каты кузгалуы, зиһен чуалуы).

**ТРАНС...**II — (кушма сүзләрнең беренче өлеше; үзенә кушылган сүз белдергән предметның аръягындагы, артындагы дигән мәгънәне аңлата; мәсәлән, *трансальпийский* — Альп таулары аръягындагы.

**ТРАНСАРКТИ'ЧЕСКИЙ** — Арктика аша үтә торган, Арктика аша...; — *трансарктический воздушный путь* — Арктика аша һава юлы.

**ТРАНСАТЛАНТИ'ЧЕСКИЙ** — трансатлантик, Атлантик океан аша йөри торган; *трансатлантический пароход* — трансатлантик пароход.

**ТРАНСГРЕ'ССИЯ** *ж. мн.* нет — трансгрессия (диңгезнең коры җирне басуы).

**ТРАНСКРИБИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — транскрипцияләү (сүзләрне ишетелгәнчә анык итеп язып алу).

**ТРАНСКРИБИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — транскрипцияләнү.

**ТРАНСКРИПЦИО'ННЫЙ** *спец.*— транскрипцион, транскрипция...-ы; *транскрипционная система* — транскрипция системасы.

**ТРАНСКРИ'ПЦИЯ** *ж. спец.*— транскрипция (1. *только ед.* авазлары барлык нечкәлекләрнең язу чаралары белән бирелүе; 2. хәрефләрнең башка төрле язу билгеләре белән бирелүе; 3. транскрипцияләү өчен кирәк булган билгеләр системасы; 4. *муз.* бер тавышка яки инструментка язылган музыка әсәрен икенче тавышка яки инструментка көйләү).

**ТРАНСЛИ'РОВАТЬ** *сов. и несов.*—трансляцияләү (радиодан).

**ТРАНСЛИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— трансляцияләнү; *сегодня транслируется концерт из консерватории* — бүген консерваториядән концерт трансляцияләнә.

**ТРАНСЛИТЕРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — транслитерация (бер әлифба хәрефләрен башка әлифба хәрефләре белән алыштырып язу).

**ТРАНСЛЯЦИО'ННЫЙ** — трансляция...-ы; трансляцияләү...-ы; *трансляционный узел* — трансляция узелы.

**ТРАНСЛЯ'ЦИЯ** *ж.*—трансляция, трансляцияләү (1. тавышны радио яки телефон аркылы ишеттерү; 2. шул юл белән тапшырылган нәрсәләр; *трансляция концерта из зала консерватории* — консерватория залыннан концерт трансляцияләү).

**ТРАНСМИССИО'ННЫЙ** *тех.*— трансмиссия...-ы; трансмиссион; *трансмиссионный ремень* — трансмиссия каешы.

**ТРАНСМИ'ССИЯ** *ж. тех.*— трансмиссия (механик энергияне двигательдән каешлар ярдәмендә машинага күчерә торган корылма).

**ТРАНСОКЕА'НСКИЙ** —океан аша..., океан аша йөри торган; *трансокеанский пароход* — океан аша йөри торган пароход.

**ТРАНСПАРА'НТ** *м. спец.*— транспарант (1. сызыксыз кәгазьгә туры язу өчен, аның астына куела торган кара сызыклы кәгазь; 2. артыннан яктыртып күрсәтелә торган рамга киереп куелган, рәсемле үтә күренмәле материя — иллюминацияләр вакытында кулланыла).

**ТРАНСПЛАНТА'Т** *м. мед. бот.*— трансплантат (икенче урынга яки икенче организмга күчерелә торган орган яки тукыма кисәге).

**ТРАНСПЛАНТА'ЦИЯ** *ж. мед. бот.*— трансплантация (тукыманы яки органны икенче бер урынга яки башка организмга күчерү, күчереп утырту).

**ТРАНСПОЗИЦИО'ННЫЙ** *книж. муз.* — транспозиция...-ы; транспозицион (музыка әсәрен бер тоннан икенче тонга күчерә торган).

**ТРАНСПОЗИ'ЦИЯ** *ж. книж. муз.*— к. транспонировка.

**ТРАНСПОЛЯ'РНЫЙ** — к. трансарктический.

**ТРАНСПОНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. *книж.* күчерү, күчереп кую; 2. *муз.* (музыка әсәрен) бер тоннан икенче тонга күчерү, үзгәртеп башка тонга салу.

**ТРАНСПОНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж. муз.*— 1. күчерелү, күчереп куелу; 2. үзгәртеп башка тонга салыну.

**ТРАНСПОНИРО'ВКА** *ж.*— 1. *только ед.* к. транспонировать; 2. *муз.* үзгәртеп башка тонга салынган музыкаль әсәр.

**ТРА'НСПОРТ** *м.*— тра́нспорт (1. бер урыннан икенче урынга йөк һәм пассажирлар ташу; 2. йөк һәм пассажирлар ташу средстволары — автомобиль, трамвай һ. б.; *железнодорожный транспорт* — тимер юл транспорты; *водный транспорт*— су транспорты; *гужевой транспорт* — җигүле транспорт; *воздушный транспорт* — һава транспорты; 3. берьюлы китерелгән йөк; 4. *воен.* судно, хәрби судно; *минный транспорт* — мина транспорты.

**ТРАНСПО'РТ** *м. бухг.*— транспо́рт (сумманы икенче биткә күчерү).

**ТРАНСПОРТЁ'Р** *м.*—транспортёр (1. *тех.* йөкләрне бер урыннан икенче урынга бертуктаусыз күчереп тора торган машина; 2. *тех.* гаражларда автомобильне борып куя торган әйләнмәле платформа; 3. *спец.* йөк ташу эшләрен алып бара торган учреждение яки аерым кеше).

**ТРАНСПОРТЁ'РНЫЙ** *спец.*— транспортёр...-ы; *транспортёрная лента* — транспортёр лентасы.

**ТРАНСПОРТИ'Р** *м. спец.*— транспортир, почмак үлчәгеч (чертёж ясау приборы).

**ТРАНСПОРТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— ташу, йөртү, күчерү, илтү; *транспортировать грузы* — йөк ташу.

**ТРАНСПОРТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— ташылу, күчерелү.

**ТРА'НСПОРТНИК** *м.* — транспортчы, транспортта эшләүче.

**ТРА'НСПОРТНЫЙ** — транспорт...-ы; *транспортные средства* — транспорт средстволары.

**ТРАНСПО'РТНЫЙ** *бухг.* — икенче биткә күчерелгән (бухгалтерлар кенәгәсендә бер биттән икенче биткә күчереп язылган); *транспортные записи* — икенче биткә күчерелгән язмалар.

**ТРАНСФЕ'Р** *м. мн.* нет, *фин.*— трансфер (акчаны бер банктан икенче банкка, бер илдән икенче илгә яки бер кеше хисабыннан икенче кеше хисабына күчерү).

**ТРАНСФОРМА'ТОР** *м.*— трансформатор (1. *физ. тех.* бер көчәнештәге алмаш токны икенче көчәнештәге алмаш токка әверелдерү аппараты; 2. *театр.* кыяфәтен бик тиз үзгәртеп, бер үк вакытта төрле рольләрне башкаручы актёр; 3. *театр.* оптикадан файдаланып бер нәрсәне башка нәрсә итеп күрсәтә торган фокусчы).

**ТРАНСФОРМА'ТОРНЫЙ** — трансформатор ...-ы; *трансформаторная будка* — трансформатор будкасы.

**ТРАНСФОРМА'ЦИЯ** *ж.* — трансформация (1. *книж.* берәр нәрсәнең кыяфәтен, формасын үзгәртү, әвереллерү; 2. *только ед. физ. тех.* трансформатор ярдәме белән алмаш токның көчәнеше үзгәртелү).

**ТРАНСФОРМИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *биол.*— трансформизм (хайваннар һәм үсемлекләр

дөньясында төрләрнең үзгәрүчәнлеге турындагы тәгълимат).

**ТРАНСФОРМИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. *книж.* үзгәртү, әвереләдерү; 2. *физ.* (алмаш токның) көчәнешен үзгәртү.

**ТРАНСФОРМИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *несов. страд. книж. физ. тех.* үзгәртелү, әверелдерелү, көчәнеше үзгәртелү; 2. *сов.* и *несов.* бөтенләй үзгәрү, икенче кыяфәткә керү.

**ТРАНСФУ'ЗИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — трансфузия (бер кешегә икенче кеше канын җибәрү).

**ТРАНСЦЕНДЕНТАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — трансцендентализм (трансцендентал төшенчәләрне тануга нигезләнгән идеалистик философия тәгълиматы).

**ТРАНСЦЕНДЕНТА'ЛЬНЫЙ** *филос.* — трансценденталь (идеалистик философиядә — тәҗрибәдән тыш тора торган, тәҗрибә белән бәйләнмәгән).

**ТРАНСЦЕНДЕ'НТНЫЙ** — трансцендент (1. *филос.* идеалистик философиядә — тәҗрибә белән танып-белеимн торган, тәҗрибә белән белеп булмый торган; *трансцендентный мир* — трансцендент галәм; 2. *мат.* алгебра гамәлләре белән хисаплап булмый торган яки алгебраик тәгъбирләр белән аңлатып булмый торган; *трансцендентная математика* — трансцендент математика).

**ТРАНШЕ'ЙНЫЙ** *воен.* — траншея ...-ы, траншеяда кулланыла торган; *траншейные орудия* — траншея орудиеләре.

**ТРАНШЕ'Я** *ж.* — траншея (1. *воен.* тирән һәм озын окоп; 2. *горн.* тау эшендә тау токымнары алу өчен казылган озын чокыр).

**ТРАП** *м.* — трап (1. *мор.* басма — судноларга кереп-чыгып йөрү басмасы; 2. *тех.* идәндәге суны агызу өчен эшләнгән тишек; 3. *ав.* дирижабль идәненең басмасы).

**ТРА'ПЕ'ЗА** *ж.* — трапеза (1. *церк.* монастырьда күмәк кеше өчен аш өстәле; 2. *устар. теперь шутл.* аш ашау, аш табыны; 3. *церк.* чиркәүнең арткы ягы, арткы өлеше; 4. монастырьда — ашханә).

**ТРАПЕ'ЗНИК** *м. церк.* — трапезник (1. монастырьда: аш табынындагы тәртипне күзәтеп торучы монах; 2. чиркәүдә: түбән дәрәҗәле чиркәү хезмәтчесе).

**ТРАПЕ'ЗНИЧАТЬ** *несов. устар.* — 1. к. трапезовать; 2. *ритор.* мәҗлес корып утыру, сыйлану, ашап-эчеп утыру.

**ТРАПЕ'ЗОВАТЬ** *несов. устар. церк.* — ашау, табында утыру.

**ТРАПЕЦИЕВИ'ДНЫЙ** — трапециясыман, трапециягә охшаган.

**ТРАПЕ'ЦИЯ** *ж.* — трапеция (1. *мат.* ике кыры бер-беренә параллель булган, калган ике кыры бер-беренә параллель булмаган дүртпочмак; 2. *спорт.* ике бауга асылган аркылы агачтан гыйбарәт гимнастика ясау снаряды).

**ТРАПЕЦОИДА'ЛЬНЫЙ** *спец.* — к. трапециевидный.

**ТРАС** *м. мн.* нет, *мин.* — трас (цементка кушыла торган тау токымы).

**ТРА'ССА** *ж.* — трасса (1. *спец.* юл салу, канал үткәрү эшләренең сызымы, чертёжы; 2. юл, канал һ. б. сызыгының юнәлеше; *трасса Волго-Донского канала* — Идел-Дон каналының трассасы).

**ТРАССА'НТ** *м. фин.* — трассант (күчерү векселе бирүче).

**ТРАССА'Т** *м. фин.* — трассат (күчерү векселе буенча түләүче).

**ТРАССИ'РОВАТЬ** I. *сов.* и *несов.* — 1. *спец.* трассалау, трасса салу, трассасын билгеләү; 2. *воен.* эз калдырып очу, ялтыраган эз калдырып очу (пуля, снаряд турында).

**ТРАССИ'РОВАТЬ** II *сов.* и *несов. фин.* — күчерү векселе бирү (акча түләүне башка кешегә күчерү).

**ТРАССИ'РОВАТЬСЯ** I *несов. страд. спец.* — трассалану, юлы( трассасы) билгеләнү.

**ТРАССИ'РОВАТЬСЯ** II *несов. страд. фин.* — күчерү векселе бирелү.

**ТРА'ТА** *ж.* — 1. *только ед.* к. тратить; 2. расход, чыгым; *предстоят большие траты* — алда бик күп расходлар тора.

**ТРА'ТИТЬ** *несов.* — 1. тоту; *тратить деньги* — акча тоту; 2. сарыф итү; *тратить силы* — көч сарыф итү; 3. үткәрү, югалту, әрәм итү; *тратить время* — вакыт әрәм итү.

**ТРА'ТИТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* акча тоту, расходлану; 2. *страд.* тотылу; *тратится много денег* — күп акча тотыла.

**ТРА'ТТА** *ж. фин.* — тратта, күчерү векселе.

**ТРА'УЛЕР** *м. спец.* — к. тральщик 1.

**ТРА'УР** *м. мн.* нет — 1. траур, матәм (үлгән кеше өчен кайгы белдерү халәте, бу белдерү кара кием киюдән һ. б. гыйбарәт); 2. *разг. фам. шутл.* (тырнаклар астындагы) кара, пычрак; *длинные ногти — в трауре* — озын тырнаклары астында пычрак.

**ТРА'УРНИЦА** *ж. зоол.* — кара күбәләк (канатына буй-буй кызыл төшкән була).

**ТРА'УРНЫЙ** — 1. траур ...-ы, матәм ...-ы; *траурный марш* — матәм маршы; *траурная одежда* — траур киеме; 2. *перен. книж.* траурлы, бик кайгылы.

**ТРАФАРЕ'Т** *м.* — трафарет (1. *спец.* бизәк төшерә торган өлге, калып; 2. *спец.* кисеп эшләнгән хәрефләрдән һәм цифрлардан төзелгән язу; 3. *перен.* искергән, һәркемгә билгеле үрнәк, шаблон; *мыслить по трафарету* — шаблон буенча фикер йөртү).

**ТРАФАРЕ'ТИТЬ** *несов. спец. просторечь.* — трафарет буенча бизәк төшерү; *трафаретить потолок* — трафарет буенча түшәмгә бизәк төшерү.

**ТРАФАРЕ'ТКА** *ж.* — трафаретка (1. *спец.* к. трафарет 1; 2. *спец.* трафарет буенча бизәк төшерә торган пумала; 3. *горн.* алтын юганда — шлюз төбендә алтын тота торган агач борыс).

**ТРАФАРЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — трафаретлык (шаблон буенча эшләнгәнлек, искергәнлек, чәйнәлгәнлек).

**ТРАФАРЕ'ТНЫЙ** — трафарет ...-ы; трафарет буенча эшләнгән; *трафаретный рису-*

*нок* — трафарет буенча эшләнгән рәсем; 2. трафарет ..., чәйнәлгән, шаблон буенча эшләнгән; *трафаретная мысль* — трафарет фикер.

**ТРАФАРЕ'ТЧИК** *м. спец.* — трафаретчы (1. трафаретлар хәзерләүче оста; 2. трафаретлар буенча эшләүче оста).

**ТРА'ФИТЬ** *несов. простореч.* — 1. уңышлы башкару, оста башкару; 2. (*угождать*) ярау, күңелен билдыру.

**ТРАХ** — 1. *межд. разг.* шалт, шарт; 2. *в знач. сказ. простореч.* шалт берне, шап берне (шалт итеп сукты, шап итеп сукты); *он его трах по спине* — ул аның аркасына шап берне.

**ТРА'ХАТЬ** *несов. простореч.* — к. трахнуть.

**ТРАХЕИ'Т** *м. мн.* нет, *мед.* — трахеит (бугаз катары).

**ТРАХЕОТОМИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — трахеотомия (сулыш юлы тыгылса, бугазны ярып махсус көпшә кую).

**ТРАХЕ'Я** *ж.* — трахея (1. *анат.* сулыш алу бугазы; 2. *зоол.* кайбер бөҗәкләрдә тын алу көпшәсе; 3. *бот.* үсемлекләрдә дым үткәрү көпшәсе).

**ТРА'ХНУТЬ** *сов. простореч.* — 1. гөрс итеп ату; *трахнуть из ружья* — мылтыктан гөрс итеп ату; 2. шалт (шап) итеп сугу; *трахнуть кулаком по столу* — йодрык белән өстәлгә шап итеп сугу; 3. челпәрәмә китерү, вату; *трахнуть графин* — графинны челпәрәмә китерү. ◇ **Опять, небось, вчерась трахнул за галстук?** (Чехов) — кичә син тагын салгансың булса кирәк?

**ТРА'ХНУТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. шап итеп төшү, шап итеп егылу, гөрс итеп егылу; *тарелка трахнулась на пол* — тәлинкә идәнгә шап итеп төште; 2. бик каты бәрелү, бик нык бәрелү; *трахнулся головой о перекладину* — башы белән җепсәгә бик каты бәрелде.

**ТРАХО'МА** *ж. мн.* нет, *мед.* — трахома (йогышлы күз авыруы).

**ТРАХОМАТО'ЗНЫЙ** — 1. трахомалы; *трахоматозный больной* — трахомалы авыру; 2. трахома ...-ы; трахомадан дәвалый торган; *трахоматозная клиника* — трахомадан дәвалый торган клиника.

**ТРАХ-ТАРАРА'Х** *межд. разг. фам.* — шап, шарт, шалт, гөрс-гөрс, гөр-гөр (берәр нәрсә төшкәндә, күк күкрәгәндә, туп атканда булган тавышка охшату ымлыгы).

**ТРЕ'БА** I *ж. церк.* — 1. корбан чалу, корбан; 2. гыйбадәт йоласы (мәсәлән, никах уку, җеназа уку).

**ТРЕ'БА** II *в знач. сказ. обл.* — кирәк; *об этом треба подумать* — бу турыда уйлап карарга кирәк.

**ТРЕ'БНИК** *м. церк.* — гыйбадәт китабы, дога китабы, догалык.

**ТРЕ'БОВАНИЕ** *ср.* — 1. *только. ед.* таләп; сорау; *по требованию суда* — суд(ның) таләбе буенча; 2. *офиц.* требование; *выписать требование на дрова* — утын алырга требование язу.

**ТРЕ'БОВАТЕЛЬ** *м. офиц.* — таләп итүче.

**ТРЕ'БОВАТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — таләпчәнлек, таләп итүчәнлек.

**ТРЕ'БОВАТЕЛЬНЫЙ** — 1. таләпчән, таләп итүчән; *требовательный начальник* — таләпчән начальник; 2. (*разборчивый*) талымлаучан, сайланучан.

**ТРЕ'БОВАТЬ** *несов.* — 1. таләп итү, сорау; *растение требует ухода* — үсемлек карауны таләп итә; 2. кирәк булу, мохтаҗ булу; *больной требует ухода* — авыру кешегә тәрбия кирәк; 3. чакыру, чакырту; *меня требуют домой* — мине өйгә чакырталар.

**ТРЕ'БОВАТЬСЯ** *несов.* — 1. кирәк (булу), мохтаҗ (булу), зарур (булу); *заводу требуются следующие материалы* — заводка түбәндәге материаллар кирәк; *на это требуется много времени* — моңа бик күп вакыт кирәк; 2. *страд.* таләп ителү, соралу.

**ТРЕБУХА'** *ж. мн.* нет — 1. эчәк-бавыр (суелган хайванның эченнән чыккан нәрсәләр); 2. *перен. простореч. презрит.* чүп-чар.

**ТРЕБУШИ'НА** *ж. мн.* нет, *простореч. обл.* — к. требуха 1.

**ТРЕВО'ГА** *ж.* — 1. курку, тәшвиш, шом, шик, шау-шу; *его охватила тревога* — аны шом басты; 2. *воен., спец.* тревога (куркыныч турында сигнал).

**ТРЕВО'ЖИТЬ** *несов.* — 1. борчу, тынычсызлау; *меня тревожит отсутствие писем от друга* — дустымнан хат килмәү мине борчый; 2. комачаулау; 3. авырттыру, борчу, ярсыту (авырткан урынга тиеп).

**ТРЕВО'ЖИТЬСЯ** *несов.* — 1. борчылу, тынычсызлану, тәшвишләнү; *тревожиться за сына* — улы турында борчылу; 2. мәшәкатьләнү, борчылу; *напрасно вы тревожитесь, всё сделаю сам* — юкка гына мәшәкатьләнәсез, барын да үзем эшләрмен.

**ТРЕВО'ЖНЫЙ** — 1. шомлы, тәшвишле; *тревожные слухи* — шомлы хәбәрләр; 2. тревога ...-ы; *тревожный сигнал* — тревога сигналы.

**ТРЕВОЛНЕ'НИЕ** *ср. книж. шутл.* — тәшвиш, зур тынычсызлык, бик күп борчылулар.

**ТРЕГЛА'ВЫЙ** — 1. өч гөмбәзле; *треглавая церковь* — өч гөмбәзле чиркәү; 2. *поэт.* өч башлы; *треглавый змей* — өч башлы елан.

**ТРЕГУ'БЫЙ** *разг. шутл.* — китек иренле, куян иренле.

**ТРЕД-ЮНИО'Н** *м.* — тред-юнион (Англиядә һәм аның доминионнарында профессионал союз).

**ТРЕ'ЗВЕННИК** *м.*, **ТРЕ'ЗВЕННИЦА** *ж. книж. разг. шутл.* — аракы эчми торган кеше.

**ТРЕ'ЗВЕННЫЙ** — 1. саф акыллы; 2. *перен неодобр.* үз җаен гына карый торган, вакчыл.

**ТРЕЗВЕ'ТЬ** *несов.* — 1. айну, айный бару; 2. *перен.* айну, хыяллардан арыну.

**ТРЕЗВО'Н** *м. мн.* нет — 1. бөтен чаңнарны берьюлы кагу (чиркәүдә); 2. *мор. устар.* чаң кагу (корабльдә янгын сигналы); 3. *перен. разг. фам. шутл.* хәбәр-

ләр, имеш-мимешләр, гайбәтләр; *пошёл трезвон по всему городу* — бөтен шәһәргә хәбәрләр тарала башлады; 4. *перен. разг. фам.* гауга, җәнҗал, ыгы-зыгы, шау-шу.

**ТРЕЗВО'НИТЬ** *несов.*— 1. бөтен чаңнарны (кыңгырауларны) берьюлы кагу; 2. *мор. устар.* чаң сугу (мәсәлән, янгын чыкканны белдереп); 3. *простореч.* бик нык шалтырату; 4. *перен. разг. фам. шутл.* хәбәрләр тарату, гайбәтләр тарату.

**ТРЕ'ЗВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. аеклык; аек булу; 2. аракы эчмәү; 3. *перен.* аеклык, сәламәтлек, сафлык; *трезвость суждений* — фикер йөртүнең аеклыгы.

**ТРЕ'ЗВЫЙ** — 1. аек, эчмәгән; *быть в трезвом состоянии* — аек хәлдә булу; 2. *только полн. формы. разг.* аракы эчмәүче..., аракы эчми торган; 3. *перен.* саф, аек; *трезвый взгляд на события* — вакыйгаларга аек караш.

**ТРЕЗУ'БЫЙ** — өч тешле; *трезубая острога* — өч тешле чәнечке.

**ТРЕК** *м. спорт.*— трек (велосипедларда узышу юлы).

**ТРЕКЛЯ'ТЫЙ** *простореч.*— каһәр суккан, ләгънәт төшкән, мәлгунь; *зима — треклятое время* (Горький) — кыш — каһәр суккан вакыт.

**ТРЕЛЕВА'ТЬ** *несов. тех.*— тарттыру, тарттырып илтү (киселгән агачларны тарттырып урманнан юлга чыгарып кую).

**ТРЕЛЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — тарттырылу, тарттырып илтелү (киселгән агачлар турында).

**ТРЕ'ЛИТЬ** *несов. разг.*— чут-чут итеп сайрау; *соловей трелит* — сандугач чут-чут итеп сайрый.

**ТРЕЛЬ** I *ж.*— тавыш калтырату (сайраганда, җырлаганда).

**ТРЕЛЬ** II *ж. тех.*— трель (урманнан юлга чыгарылган, тарттырылган агач өелә торган урын).

**ТРЕЛЬЯ'Ж** *м.*— трельяж (1. үрмәле үсемлекләрне үрмәләтү өчен ясалган рәшәткә; 2. өч бүлемтекле көзге).

**ТРЕМОЛИ'РОВАТЬ** *несов. муз.*— тавыш калтырату, калтыратып яңгырату (тавышны).

**ТРЕ'МОЛО** *ср. муз.*— тавыш калтырау, калтыраган тавыш.

**ТРЕН** *м. устар.*— күлмәк итәге (хатын-кызларның).

**ТРЕНА'Ж** *м. мн.* нет, *спорт.*— к. тренировка.

**ТРЕ'НЕР** *м. спорт.*— тренер (спортта күнегү эшләренең җитәкчесе); *тренер футбольной команды* — футбол командасының тренеры.

**ТРЕ'НЕРСКИЙ** — тренер...-ы; тренерлар...-ы; *тренерская работа* — тренер эше.

**ТРЕ'НЗЕЛЬ** *м. спец.*— трензель (тезгеннәрне тартканда атның аңкавына тиеп башын күтәртә торган авызлык).

**ТРЕНЗЕ'ЛЬКА** *ж. спец.*— трензель чылбыры.

**ТРЕ'НЗЕЛЬНЫЙ** — трензель...-ы, трензельле; *трензельные поводья* — трензельле тезгеннәр.

**ТРЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* ышкылу; *движущиеся части машин изнашиваются от трения* — машинаның хәрәкәт итә торган кисәкләре ышкылудан туза; 2. *перен. только мн.* тынышмау, низаг, ара начар булу; *трения с заведующим* — мөдир белән ара начар булу.

**ТРЕНИРО'ВАННЫЙ** — 1. *спорт.* күнектерелгән, өйрәтелгән; *тренированная собака* — өйрәтелгән эт; 2. *разг. шутл.* чыныккан, шомарган (берәр эштә).

**ТРЕНИРОВА'ТЬ** *несов.*— күнектерү, өйрәтү; *тренировать лошадь для верховой езды* — атны атланып йөрергә өйрәтү.

**ТРЕНИРОВА'ТЬСЯ** *несов. спорт.*— тренировка ясау, күнекмәләр ясау; *спортсмен должен постоянно тренироваться* — спортсмен һәрвакыт тренировка ясарга тиеш.

**ТРЕНИРО'ВКА** *ж.*— 1. *только ед.* к. тренировать, тренироваться; 2. күнекмә, тренировка.

**ТРЕНИРО'ВОЧНЫЙ** *спорт. спец.*— 1. тренировка...-ы; тренировка ясау...-ы, күнекмә ясау...-ы; *тренировочный самолёт* — тренировка ясау самолёты; 2. өйрәнү өчен (эшләнә торган); *тренировочный полёт* — өйрәнү өчен очу.

**ТРЕНО'ГА** *ж.*— 1. к. треножник 1; 2. *обл.* ат тышавы, кешән (атның алгы аякларын арткы бер аягына бәйләп куя торган тышау).

**ТРЕНО'ГИЙ** — 1. өч аяклы; *треногий стол* — өч аяклы өстәл; 2. *разг.* өч аякка калган (бер аягы сынган); *треногий стул* — өч аякка калган урындык.

**ТРЕНО'ЖИТЬ** *несов.*— тышаулау, кешәнләү.

**ТРЕНО'ЖИТЬСЯ** *несов. страд.*— тышаулану, кешәнләнү.

**УГОТО'ВИТЬ** *сов. книж. ритор.* — хәзерләү, әзерләү, хәстәрләү; әзерләп кую, хәзерләп кую.

**УГОТОВЛЯ'ТЬ** *несов. книж. ритор.* — к. уготовить.

**УГОТОВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж. ритор. страд.* — хәзерләнү, әзерләнү, хәзерләп куелу, әзерләп куелу.

**УГОЩА'ТЬ** *несов.* — к. угостить.

**УГОЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. угоститься; 2. *страд.* кунак ителү, сыйланылу, ашатылу-эчертелү.

**УГОЩЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. угостить; *угощение гостей* — кунакларны сыйлау; 2. сый; *хорошее угощение* — яхшы сый.

**УГРЕБА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. угрести.

**УГРЕБА'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. угрестись; 2. *страд.* көрәп җыелу, көрәп тутырылу.

**УГРЕВА'ТЕТЬ** *несов. разг.* — бетчәләнү, сыткы басу (битне, тәнне).

**УГРЕВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — бетчәле булу, сыткылы булу.

**УГРЕВА'ТЫЙ** — бетчәле, сыткылы, бетчәләп беткән, сыткы баскан.

**УГРЕВИ'ДНЫЕ** *в знач. сущ. зоол. ед.* нет — еланбалыклар отряды, еланбалыкчалар.

**УГРЕВИ'ДНЫЙ** — еланбалыксыман.

**УГРЁВИНА** *ж. мн.* нет. *простореч.* — еланбалык ите.

**УГРЕВО'Й** — бетчәле, сыткылы.

**УГРЁВЫЙ** — еланбалык ...-ы; *угрёвая кожа* — еланбалык тиресе.

**УГРЁНОК** (*мн.* угрята) *м.* — еланбалык маймычы.

**УГРЕСТИ'** *сов. простореч.* — 1. (ишкәк белән) ишеп китү, ишә-ишә китү, ишеп китеп котылу; *еле угребли от погони* — куып килүчеләрдән көчкә ишеп китеп котылдык; 2. көрәп җыю, көрәп тутыру; *угрести весь овёс в закром* — бөтен солыны бурага көрәп тутыру.

**УГРЕСТИ'СЬ** *сов. простореч.* — 1. к. угрести 1; 2. *обл.* (көрәп) җыеп бетерү, җыйнап бетерү.

**УГРЕ'ТЬ** *сов. простореч.* — җылыту, җылытып җибәрү.

**УГРЕ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — җылыну, җылынып китү.

**УГРО'БИТЬ** *сов. простореч, вульг.* — 1. үтерү; башына җитү, башын ашау; 2. *перен.* бозу, юк итү, харап итү. ◇ **Угробить чью-н. репутацию** — берәүне рисвай итү (берәр кешенең репутациясен бөтенләй юкка чыгару).

**УГРОЖА'ЕМЫЙ** *простореч.* — к. угрожающий 2.

**УГРОЖА'ТЬ** *несов.* — к. грозить.

**УГРОЖА'ЮЩЕ** *нареч.* — куркыныч(лы) итеп, куркытып; янаулы, янау белән; *угрожающе посмотреть* — янаулы караш ташлау.

**УГРОЖА'ЮЩИЙ** — 1. куркыта торган, яный торган, янаулы; 2. куркыныч, куркынычлы, хәтәр, хәвефле; *угрожающее положение* — куркынычлы хәл.

**УГРО'ЗА** — 1. куркыту, янау; *действовать угрозами* — янаулар юлы белән эш итү; 2. куркыныч, хәвеф, дәһшәт; *мы боремся с угрозой войны* — без сугыш куркынычына каршы көрәшәбез.

**УГРО'ЗЫСК** (*уголовный розыск*) *м. мн.* нет — җинаятьчеләрне эзләү бүлеге.

**УГРОРУ'С** *м. книж. старин.* — угр Русенда яшәүче.

**У'ГРО-ФИ'НСКИЙ** — угро-фин...-ы; *угро-финские языки* — угро-фин телләре.

**У'ГРО-ФИ'ННЫ** (финно-угры) *мн.* — угрофиннар (венгр, фин, карел, эстон, мордва, мари, удмурт, коми, манси һ. б. ш. телләре бер-берсенә охшаш халыклар төркеме).

**У'ГРЫ** *мн.* (*ед.* угр) — угрлар (угро-финнарның бер тармагы: монда венгрлар, хантлар һәм мансилар керә).

**УГРЫЗА'ТЬ** *несов.* — 1. *просторeч.* к. угрызть; 2. *перен. редко* газаплау, җәфалау; *его угрызает совесть* — аны вөҗданы газаплый.

**УГРЫЗА'ТЬСЯ** *несов. просторeч. страд.* — кимерелү.

**УГРЫЗЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед. просторeч. шутл.* к. угрызть; 2. *перен.* газап, җәфа, газаплану; *угрызение совести* — вөҗдан газабы.

**УГРЫ'ЗТЬ** *сов. просторeч.* — кимерү, кимереп ашап бетерү.

**УГРЮ'МЕТЬ** *несов. редко* — йөзе караңгылану, чырае сытылу, кашлары җыерылу.

**УГРЮ'МО** — караңгы чырай белән, усал итеп, төксе (карау).

**УГРЮ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет — караңгы чырайлылык, кырыслык.

**УГРЮ'МЫЙ** — 1. караңгы чырайлы; кырыс; төксе; *хозяин был старик угрюмый* (Лермонтов) — хуҗа караңгы чырайлы бер карт иде; *угрюмый взгляд* — кырыс караш; 2. *перен.* караңгы; кара; сүрән; *угрюмый лес* — караңгы урман.

**УД** *м. старин.* — әгъза (кул, аяк һ. б.).

**УДА'** *ж. старин. обл.* — кармак (сабы, җебе, калкавычы белән). ◇ **Поймать (или поддеть) на уду** *разг.* — к. удочка.

**УДА'БРИВАТЬ** *несов. разг.* — к. удобрить.

**УДА'БРИВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — к. удобряться.

**УДА'В** *м.* — буар елан, буа елан (тропик якларда яши һәм озынлыгы 5—7 метрга җитә торган агусыз елан).

**УДАВА'ТЬСЯ** *несов.* — к. удаться.

**УДАВИ'ТЬ** *сов.* — 1. (*убить*) буу, буып үтерү; 2. (*утрамбовать*) таптау, төю, таптап тыгызлау.

**УДАВИ'ТЬСЯ** *сов.* — асылынып үлү, буылу, буылып үлү.

**УДА'ВКА** *ж. спец.* — 1. элмәк, бугалак; 2. телсез кармак, үзе ясаган кармак.

**УДАВЛЕ'НИЕ** *ср. книж. мн.* нет — буылу, буу; *смерть от удавления* — буылып үлү.

**УДА'ВЛЕННИК** *м. разг.* — асылынып үлгән кеше; буып үтерелгән кеше.

**УДА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. удавить.

**УДА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. буылу, буып үтерелү; 2. тапталу, таптап тыгызлану, төелү.

**УДА'ВОВЫЕ** *зоол.* — буар еланнар семьялыгы.

**УДАЛЕ'НИЕ** *ср.* — к. удалить, удалиться.

**УДАЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет. *книж.* — ераклык, ерак булу.

**УДАЛЁННЫЙ** — 1. суырып алынган, алдырылган; *удалённый зуб* — алдырылган теш; 2. ерак, ерактагы, ерагайтылган, ераклаштырылган; *удалённые предметы* — ерактагы әйберләр.

**УДАЛЕ'Ц** *м. разг.* — батыр егет, уңган егет.

**УДАЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. ерагайту, ераклаштыру; *удалить предмет от глаз* — әйберне күздән ерагайту; 2. чыгару, чыгарып җибәрү, сөреп чыгару; *удалить посторонних из зала* — чит кешеләрне залдан чыгару; 3. *книж.* (*уволить*) эштән алу, эштән азат итү, эштән чыгару; 4. юлдан алып ташлау; *удалить соперника* — көндәшне юлдан алып ташлау; 5. *книж. спец.* алдыру, суыртту; тәннән алу; *удалить зуб* — тешне алдыру; *удалить занозу* — кадалган шырпыны тәннән алу; 6. бетерү, китәрү; *удалить пятна* — тапларны бетерү.

**УДАЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ерагаю, ераклашу; *лодка удалилась от берега* — көймә ярдан ераклашты; 2. *книж.* читләшү, читкә китү; ераклашу; *удалиться от основной темы* — төп темадан читкә китү; 3. читләшү, очрашудан качу; 4. китү, китеп бару, юнәлү; *удалиться в свою комнату* — үз бүлмәсенә китеп бару.

**УДАЛО'Й, УДА'ЛЫЙ** *нар.-поэт.* — батыр, кыю; житез, гайяр; *удалой молодец* — батыр егет; *тройка удалая* — җитез тройка.

**У'ДАЛЬ** *ж. мн.* нет — батырлык, егетлек, кыюлык, житезлек.

**УДАЛЬСТВО'** *ср.* — к. удаль.

**УДАЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. удалить.

**УДАЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. удалиться; 2. *страд.* ераклаштырылу, ерагайтылу; 3. *страд.* чыгарылу, сөреп чыгарылу; 4. *страд.* эштән азат ителү, эштән чыгарылу; 5. *страд.* юлдан алып ташланылу, читләштерелү; 6. *страд.* суыртылу, алдырылу; 7. *страд.* бетерелү, китәрелү (мәсәлән, тап һ. б.).

**УДА'Р** *м.* — 1. сугу, бәрү; ору, кундыру; *удар молотом по железу* — чүкеч белән тимергә сугу; *удар в спину* — аркага сугу; 2. чабу; *удар меча* — кылыч белән чабу; 3. сугу көче, кул көче; 4. тавыш, суккан тавыш, каккан тавыш, бәргән тавыш, гө-

релте; *удары колокола* — чаң каккан тавыш; 5. *перен.* авыр кайгы, кинәт килгән кайгы; *перенести удар* — авыр кайгы кичерү; 6. *воен.* удар, һөҗүм; *сокрушительный удар* — җимергеч удар; 7. *перен.* каты һөҗүм, удар; *удар по бюрократам* — бюрократларга каршы каты һөҗүм; 8. *(апоплексия)* башка кан йөгерү, удар. ◇ **Солнечный удар** — кояш сугу. **Испытание металла на удар** — металлның сугуга (бәрелүгә) чыдамлыгын сынау. **Удары судьбы** — язмыш рәхимсезлекләре. **В ударе быть** *разг.* — илһам булу, кәеф-дәрт булу (берәр нәрсә эшләү өчен). **Под ударом** — 1) һөҗүм астында; 2) *перен.* куркыныч хәлдә, хәвефле хәлдә. **Удар пульса** — пульс тибүе, тамыр тибүе. **Штрафной удар** *спорт.* — к. штрафной.

**УДАРЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *лингв.* басым; *логическое ударение* — логик басым; 2. басым билгесе; *поставить ударение* — басым билгесе кую; 3. *перен.* басым, басым ясау (берәр нәрсәне ассызымлап әйтү өчен).

**УДА'РЕННЫЙ** — 1. *лингв.* басымлы, басым төшкән; *ударенный гласный* — басымлы сузык; 2. сугылган, бәрелгән.

**УДА'РИТЬ** *сов.* — 1. сугу, бәрү, ору; кундыру; чабу; *ударить палкой* — таяк белән сугу; *ударить по щеке* — яңагына сугу; 2. шап итеп сугу, шак итеп сугу; *ударить по столу* — өстәлгә шап итеп сугу; 3. *(выстрелить)* ату, атып җибәрү; 4. һөҗүм итү, ташлану; *дружно ударить на врага* — дошманга каршы бердәм ташлану; 5. килеп тию, килеп бәрелү, (яшен) сугу, ату; *пуля ударила в стену* — пуля стенага килеп тиде; *молния ударила в дерево* — яшен агачны сукты; 6. тәэсир итү, (башка) килү, сугу; *вино в голову ударило* — кызыл аракы башка китте; 7. һөҗүм итү, бетерү; *ударить по бюрократам* — бюрократларга һөҗүм итү; 8. *разг.* зарар китерү, кесәгә сугу; *дороговизна ударила по покупателю* — кыйбатчылык сатып алучыларның кесәсенә сукты; 9. *простореч. фам.* ашап алу, эчеп алу, уйнап алу; *ударить по селёдке* — селёдка ашап алу; *ударить по шашкам* — шашка уйнап алу; 10. *перен. разг.* башлау, башлану, башланып китү; *ударил сильный мороз* — каты суыклар башланды. ◇ **Ударить огнивом о кремень** — чакма чагу (ут кабызу өчен). **Ударить отбой** — отбой сугу (сугыш, эш беткәнне белдереп). **Ударить тревогу** — тревога күтәрү. **Ударить набат** (в набат) — чаң сугу, набат сугу. **Ударить в колокол** — чаң кагу, чаң сугу. Гребцы **ударили в вёсла** — ишкәкчеләр ишә башладылар. **Ударили в смычки** — уйный башладылар. **Ударили в штыки** — штык сугышы башланды. От испуга **в голову ударило** — куркудан башы түнеп китте. Запахи резко **ударили в нос** — төрле исләр борынга килеп бәрелде. **Кровь ударила в голову** — к. кровь. **Лицом в грязь не ударить** — к. лицо. **Палец о палец не ударить** — к. палец. **Ударил (ударит) час** — к. час. **Ударить по рукам** — к. рука (бить по рукам, дать по рукам). **Ударить челом** — к. бить.

**УДА'РИТЬСЯ** *сов.* — 1. бәрелү, килеп бәрелү, орылу, төртелү; *удариться о дверь* — ишеккә килеп бәрелү; 2. тию, килеп тию, килеп бәрелү; *пуля ударилась в стену* — пуля стенага килеп тиде; 3. *разг.* чабу, чаба башлау, чабып китү; *заяц ударился в лес* — куян урманга чапты; 4. *разг.* мавыгу, мавыгып китү; *удариться в спорт* — спорт белән мавыгу; 5. *разг.* бирелү, бирелеп китү; *удариться в амбицию* — амбициягә бирелү; *удариться в пафос* — пафоска бирелеп китү. ◇ **Удариться из одной крайности в другую** — бер читтән икенче читкә сугылу.

**УДА'РНИК** *м.* — ударник (1. *воен.* затворның капсюльне тишеп ут кабыза торган кисәге, бәргеч; 2. *истор.* 1917 елгы февраль революциясе чорында аерым удар гаскәрләрдә хезмәт итүче гаскәри; 3. хезмәтендә, эшендә норманы арттырып үтәүче алдынгы эшче; 4. *муз.* бәрмә уен коралларында уйнаучы музыкант).

**УДА'РНИЦА** *ж.* — к. ударник 2, 3, 4.

**УДА'РНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — ударниклык, ударчылык, удар эш (эштә алдынгылык).

**УДА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — иң мөһим булу, иң әһәмиятле булу.

**УДА'РНЫЙ** — 1. бәргеч ..., бәрмә ...; бәрә торган; *ударные музыкальные инструменты* — бәрмә музыка коралларь; 2. бәрмә ..., төп һөҗүм ясаучы; *ударные части* — бәрмә частьлар; *ударное направление* — төп һөҗүм юнәлеше; 3. удар ..., ударчылык...-ы; удар эш ...-ы; *ударная бригада* — удар бригада; *ударный месяц* — удар эш ае; 4. *перен.* иң мөһим, иң әһәмиятле, көн үзәгендәге; *ударный вопрос совремённости* — хәзерге көннең көн үзәгендәге мәсьәләсе.

**УДАРЯ'ЕМЫЙ** *лингв.* — басымлы, басым төшә торган; *ударяемый гласный* — басымлы сузык.

**УДАРЯ'ТЬ** *несов.* — 1. к. ударить; 2. *разг. фам.* (хатын-кыз артыннан) йөрү, чабу.

**УДАРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — к. удариться.

**УДА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. уңышлы булу, уңышлы чыгу, уңышлы бетү, барып чыгу; уңышлы тәмамлану, уңышлы тәгәлләнү; *опыт удался* — тәҗрибә уңышлы булды; *операция удалась* — операция уңышлы чыкты; 2. уңу, (яхшы) булу, мул уңыш бирү; *овощи нынче удались* — быел яшелчәләр уңды; 3. *безл.* туры килү; барып чыгу; *ему не удалось поехать* — аңа китәргә туры килмәде (насыйп булмады); 4. *разг.* охшау; *мальчик удался в отца* — малай атасына охшаган. ◇ **Пироги не удались** — бәккән уңмады.

**УДА'ЧА** *ж.* — уңыш, бәхет.

**УДА'ЧЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — уңышлылык, бәхетлелек, эше уңа торган булу.

**УДА'ЧЛИВЫЙ** *разг.* — эше уңучан, бәхетле; эше уңа торган.

**УДА'ЧНИК** *м.*, **УДА'ЧНИЦА** *ж. разг. фам.* — бәхетле кеше, эше уңа торган кеше.

**УДА'ЧНЫЙ** — 1. уңышлы; *удачная поездка* — уңышлы сәфәр; 2. *перен.* уңышлы, шәп чыккан, яхшы чыккан; *удачная фотография* — яхшы чыккан фоторәсем.

**УДВА'ИВАТЬ** *несов.* — к. удвоить.

**УДВА'ИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. удвоиться; 2. *страд.* икеләтелү, икеләтә арттырылу, бермә-бер арттырылу.

**УДВОЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. удвоить, удвоиться; 2. *лингв.* к. редупликация.

**УДВО'ЕННЫЙ** — 1. икеләтелгән; 2. *перен.* икеләтә; *начать работать с удвоенной энергией* — икеләтә энергия белән эшли башлау; 3. *грам.* куш, ике тапкыр кабатланган.

**УДВО'ИТЬ** *сов.* — 1. икеләтә арттыру, бермә-бер арттыру, икеләтә күтәрү; *удвоить цену* — бәясен икеләтә арттыру; 2. *перен.* арттыру, көчәйтү; *игроки удвоили внимание* — уенчылар дикъкатьләрен арттырдылар.

**УДВО'ИТЬСЯ** *сов.* — 1. икеләтә арту, ике өлеш арту, икеләтә күтәрелү; бермә-бер көчәю; *сила ветра удвоилась* — җилнең көче икеләтә артты; 2. *перен.* икеләтә көчәю, икеләтә арту; *старание удвоилось* — тырышлык икеләтә көчәйде.

**УДЁБНЫЙ** *обл. спец.* — кармак белән ...; *удёбный лов трески* — тәрәч балыгын кармак белән тоту.

**УДЕВЯТЕРИ'ТЬ** *сов.* — тугыз тапкыр арттыру, тугыз өлеш арттыру.

**УДЕВЯТЕРИ'ТЬСЯ** *сов.* — тугыз тапкыр арту.

**УДЕВЯТЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. удевятерить.

**УДЕВЯТЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. удевятериться; 2. *страд.* тугыз тапкыр арттырылу.

**УДЕ'Л** *м.* — 1. *старин.* өлеш, тигән өлеш, үз өлеше; 2. *истор.* удел (борынгы Русьта — феодаль князь биләмәсендәге өлкә); 3. *поэт.* биләмә, биләгән җир; 4. *истор. доревол.* удел; патша җирләре; *департамент уделов* — уделлар департаменты (патша гаиләсенең һәм бөтен нәселенең җирләре белән идарә иткән учреждение); 5. *перен. (судьба, участь)* язмыш, тәкъдир.

**УДЕ'ЛАТЬ** *сов. обл.* — 1. эшләп кую, ясап кую; төзәтеп кую; *уделать калитку в заборе* — коймага капка ясап кую; 2. бизәлү, эшләнү; *окна уделаны резьбой* — тәрәзәләр сырлап эшләнгән.

**УДЕЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. бүлү, бүлеп бирү, өлеш бирү, өлеш чыгару; аерып бирү; *уделить кусок собаке* — эткә өлеш чыгару; *из бюджета уделить известную сумму на что-н.* — бюджеттан билгеле бер сумманы берәр нәрсәгә аерып бирү; 2. *перен.* бүлү, бирү; *уделить внимание* — игътибар бирү.

**УДЕ'ЛКА** *ж. мн.* нет, *обл. спец.* — к. уделать.

**УДЕ'ЛЫВАТЬ** *несов. обл.* — к. уделать.

**УДЕ'ЛЫВАТЬСЯ** *несов. обл., страд.* — 1. эшләнү, ясалу, төзәтелү; 2. эшләнү, бизәлү.

**УДЕ'ЛЬНЫЙ** — 1. *истор.* удел ...-ы; *удельный князь* — удел кнәзе; 2. *истор.* удел...-ы, патша ...-ы; патша җирләре ...-ы; *удельные земли* — патша җирләре; *удельное ведомство* — удел ведомствосы; 4. *физ. тех.* чагыштырма; *удельная влажность* — чагыштырма дымлылык. ◇ **Удельный вес** — 1. *физ.* чагыштырма авырлык; 2. *перен.* чагыштырмача әһәмияте, тоткан урыны.

**УДЕЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. уделить.

**УДЕЛЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. бүленү, бүлеп бирелү, өлеш чыгарылу; 2. аерып бирелү, аерылып куелу (мәсәлән, акча); 3. бирелү (вакыт, игътибар).

**У'ДЕРЖ** *м.*: **без удержу** *разг.* — тыелгысыз, тыелмыйча, туктаусыз; **без всякого удержу** — һичбер тыелгысыз; **нет удержу** *разг.* — тыеп булмый, туктатып булмый; туктата алмассың; **не знать удержу** *в чем (разг.)* — тыела алмау, чаманы белмәү.

**УДЕРЖА'НИЕ** *ср.* — 1. к. удержать 8, 9; 2. *канц.* тотым, тотым суммасы (тотылып алып калган акча).

**УДЕРЖА'ТЬ** *сов.* — 1. тоту, тотып калу, (кулдан) ычкындырмау, төшермәү; *удержать в руках* — кулда тотып калу; 2. тоту, тотып алып калу; *удержать его, женихa-то, родители не смогли* (Чехов) — ә кияүне кызның ата-аналары тотып алып кала алмадылар; 3. тотып калу, тыю, туктату; *кучер не удержал лошадей* — кучер атларын тотып кала алмады; 4. басу, тыю, тыеп калу; *удержать гнев* — ачуын басу; 5. тыелып калу; *удержать крик* — кычкырып җибәрүдән тыелып калу; 6. йотып калу; *удержать слёзы* — күз яшьләрен йотып калу; 7. тыеп калу, тотып калу, туктатып калу; юл куймау; *он тебя от пьянства удержал* — ул сине эчүдән туктатып калды; *удержать от безрассудного поступка* — ахмак эштән тыеп калу; 8. саклау, тоту; саклап калу; *удержать в памяти* — хәтердә саклау; *чемпион удержал за собой первое место* — чемпион беренчелекне үзендә саклап калды; 9. тотып калу, тотып алып калу; *удержать из гонорара* — гонорардан тотып калу. ◇ **Удержать язык** — телне тыю. **Материя удержала краску** — материянең төсе уңмаган (буявы китмәгән).

**УДЕРЖА'ТЬСЯ** *сов.* — 1. тотынып калу, басып калу, торып калу, егылмый калу; *еле удержался на ногах* — аягында көчкә басып калды; 2. (үз урынында) торып калу, саклап калу, тотып калу; *отряд удержался на прежних позициях* — отряд элекке позициясен тотып калды; *он удержался на службе* — ул үз хезмәтендә торып калды; 3. тыелу, тыелып калу, саклап калу, чыдап калу, түзеп калу; *удержаться от смеха* — көлүдән тыелып калу.

**УДЕ'РЖИВАТЬ** *несов.* — к. удержать.

**УДЕ'РЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. удержаться; 2. *страд.* тыелу, туктатылу, юл куелмау; 3. *страд.* тотылу, тотып калыну.

**УДЕСЯТЕРЁННЫЙ** — ун тапкыр арттв-

рылган, унлата арттырылган, ун өлеш арттырылган.

**УДЕСЯТЕРИ'ТЬ** *сов.*— **1.** ун тапкыр арттыру, ун өлеш арттыру, унлата арттыру; *удесятерить сумму* — сумманы ун өлеш арттыру; **2.** *перен.* бик нык арттыру, күп мәртәбә көчәйтү; *удесятерить силы* — көчләрне бик нык арттыру.

**УДЕСЯТЕРИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. унлата арту, ун өлеш арту, ун тапкыр арту; *доходы удесятерились* — доходлар ун тапкыр артты; 2. *перен.* күп мәртәбә арту, күп тапкыр көчәю.

**УДЕСЯТЕРЯ'ТЬ** *несов.*— к. удесятерить.

**УДЕСЯТЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. удесятериться; 2. *страд.* ун кат арттырылу, ун өлеш көчәйтелү.

**УДЕШЕВИ'ТЬ** *сов.*— арзанайту; бәясен төшерү, бәясен киметү.

**УДЕШЕВИ'ТЬСЯ** *сов.*— арзанаю, бәясе төшү, бәясе кимү.

**УДЕШЕВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. удешевить.

**УДЕШЕВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. удешевиться; 2. *страд.* арзанайтылу, бәясе киметелү, төшерелү.

**УДИВИ'ТЕЛЬНО** — 1. *нареч.* гаҗәп, искиткеч, гаять дәрәҗәдә, хәйран калырлык; *он удивительно изменился* — ул искиткеч үзгәргән; 2. *в знач. сказ.* гаҗәп, сәер, кызык; *удивительно, как ты не простудился в такой мороз* — гаҗәп, сиңа шундый суыкта ничек салкын тимәгән.

**УДИВИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гаҗәплек, сәерлек; искиткеч булу.

**УДИВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. ис китәрлек, гаҗәпләнерлек; *да что ж тут удивительного?*— монда гаҗәпләнерлек ни бар соң? 2. искиткеч, гаҗәеп; гадәттән тыш шәп; *здоровье у него было удивительное* —аның сәламәтлеге искиткеч иде. ◇ **И не удивительно** *разг.*— гаҗәп тә түгел, гаҗәпләнергә урын да юк (нигә икәне үзеннән-үзе аңлашыла).

**УДИВИ'ТЬ** *сов.*— гаҗәпләндерү, гаҗәпкә калдыру, таңга калдыру, ис китәрү, шаккатыру; хәйран калдыру.

**УДИВИ'ТЬСЯ** *сов.*— ис китү, гаҗәпләнү, гаҗәпкә калу, таң калу, хәйран калу.

**УДИВЛЕ'НИЕ** *ср.*— гаҗәпләнү, гаҗәпкә калу, ис китү, таң калу; хәйран калу, аптырау. ◇ **На удивление** *кому-чему.* (*разг.*)— гаҗәп яхшы, искиткеч яхшы, соклангыч.

**УДИВЛЁННО** *нареч.*— гаҗәпсенеп, исе китеп.

**УДИВЛЁННЫЙ** — гаҗәпләнгән, гаҗәпсенгән; исе китеп..., хәйран булып...; *смотреть удивлёнными глазами* — гаҗәпсенгән күз белән карау.

**УДИВЛЯ'ТЬ** *несов.*— к. удивить.

**УДИВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. удивиться.

**УДИЛА'** *мн. спец.* (*ед.* удило)— авызлык (йөгәндә). ◇ **Закусить удила** — к. закусить I.

**УДИ'ЛИЩЕ** *ср.*— кармак сабы.

**УДИ'ЛЬНЫЙ** I — балык тоту...-ы; *удильные принадлежности* — балык тоту кирәк-яраклары.

**УДИ'ЛЬНЫЙ** II *спец.*— авызлык...-ы.

**УДИ'ЛЬЩИК** *м.*, **УДИ'ЛЬЩИЦА** *ж.*— кармакчы, кармак салучы, балык каптыручы.

**УДИРА'ТЬ** *несов. разг. фам.*— к. удрать.

**УДИ'ТЬ** *несов.*— кармак салу, балык каптыру, кармак белән балык тоту.

**УДИ'ТЬСЯ** *несов. безл.*— балык кабу, балык эләгү (кармакка).

**УДЛИНЕ'НИЕ** *ср.*— 1. к. удлинить, удлиниться; 2. озайтма, ялганма (озынайтылган яки ялганган өлеш).

**УДЛИНЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — озынчалык, сузынкылык.

**УДЛИНЁННЫЙ** — 1. озынайтылган, сузылган; 2. *(вытянутый в длину)* озынча, сузынкы.

**УДЛИНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.*— озынайткыч озынайта торган; оз(ын)айту ...-ы; ялгау ...-ы; *удлинительный прибор* — озынайткыч прибор; *удлинительный способ* — озынайту ысулы.

**УДЛИНИ'ТЬ** *сов.*— озайту, озынайту, сузу, сузылдыру; *удлинить рукав* — җиңне озынайту; *удлинить рабочий день* — эш көнен озайту.

**УДЛИНИ'ТЬСЯ** *сов.*— озынаю, озаю; сузылу.

**УДЛИНЯ'ТЬ** *несов.*— к. удлинить.

**УДЛИНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. удлиниться; 2. *страд.* озайтылу, озынайтылу.

**УДМУ'РТ** *м.*— удмурт (ир кеше).

**УДМУ'РТКА** *ж.*— удмурт хатыны, удмурт кызы, удмурт хатын-кызы.

**УДМУ'РТСКИЙ** — 1. удмурт ...-ы; *удмуртский язык* — удмурт теле; 2. Удмуртия ...-ы; *Удмуртская АССР* — Удмуртия АССР.

**УДМУ'РТЫ** *мн.*— удмуртлар (башлыча хәзерге Удмуртия АССРда яши торган халык).

**УДО'БНО** — 1. *нареч.* уңайлы итеп, җайлы итеп, җайлап, уңайлап; *удобно усесться* — җайлап утырышу; 2. *в знач. сказ. безл.* уңайлы, җайлы, кулайрак, уңайлырак; *мне удобно поехать в отпуск осенью* — миңа отпускыга китү өчен көз уңайлы. ◇ **Удобно ли это сказать?**— моны әйтү ярармы икән? Моны әйтү килешерме икән?

**УДО'БНОСТЬ** *ж. мн.* нет — җайлылык, уңайлылык; уңай булу, кулай булу.

**УДО'БНЫЙ** — 1. уңайлы, җайлы; ипле; көйле; *кресло, удобное для сидения* — утырырга җайлы кресло; 2. кулай, уңайлы, уңай; *выбрать удобное время* — уңайлы вакыт туры китерү.

**УДОБОВАРИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*—1. җиңел сеңә торган булу, җиңел үзләштерелә торган булу; 2. *перен.* җиңел аңларлык булу.

**УДОБОВАРИ'МЫЙ** *книж.*— 1. җиңел сеңдерешле, җиңел сеңә торган; җиңел үзләштерелә торган; *удобоваримая пища* — җиңел үзләштерелә торган азык; 2. *перен. ирон.* җиңел аңлашыла торган, аңларга җиңел, җиңел аңлаешлы.

**УДОБОИСПОЛНИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет,

*книж.*— җиңел башкарылучанлык, җиңел үтәлүчәнлек.

**УДОБОИСПОЛНИ'МЫЙ** *книж.*— җиңел башкарыла торган, башкаруы җиңел; җиңел үтәлә торган, җиңел башкарылмышлы, җиңел үтәлешле.

**УДОБОПОНЯ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— җиңел аңлаешлылык, җиңел аңлашылучанлык.

**УДОБОПОНЯ'ТНЫЙ** *книж.*— җиңел аңлаешлы, җиңел аңлашыла торган.

**УДОБОПРОИЗНОСИ'МОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— җиңел әйтелешлелек, җиңел әйтелүчәнлек.

**УДОБОПРОИЗНОСИ'МЫЙ** *книж.* — 1. җиңел әйтелешле, әйтергә җиңел, җиңел әйтелүчән; 2. *перен. шутл.* (*пристойный*) әйтергә ярый торган, әдәпле (сүз).

**УДОБОУСВОЯ'ЕМЫЙ** *книж.*—1. җиңел, җиңел сеңдерешле, җиңел үзләштерелә торган; *удобоусвояемая пища* — җиңел азык; 2. *перен.* җиңел аңларлык, җиңел аңлаешлы; *рассказать в удобоусвояемой форме* — җиңел аңларлык итеп сөйләп бирү.

**УДОБОЧИТА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — җиңел укылучанлык, укырга җиңел булу.

**УДОБОЧИТА'ЕМЫЙ** *книж.*— 1. укырга җиңел, җиңел укылышлы, җиңел укыла торган; 2. *перен. шутл.* (*пристойный*) укырга оят булмаган, әдәпле.

**УДОБРЕ'НИЕ** *ср.*— 1. к. удобрить; 2. ашлама (тирес, черемә һ. б.); *минеральные удобрения* — минераль ашламалар.

**УДО'БРЕННЫЙ** — ашланган, ашлама кертелгән.

**УДОБРИ'ТЕЛЬНЫЙ** *устар.*— җир ашлау...-ы; җир ашлый торган; *удобрительные работы* — җир ашлау эшләре.

**УДО'БРИТЬ** *сов.*— ашлау, ашлама кертү, яхшырту (җирне, туфракны).

**УДОБРЯ'ТЬ** *несов.*— к. удобрить.

**УДОБРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— ашланылу, ашлама кертелү, яхшыртылу (җир).

**УДО'БСТВО** *ср.*—1. уңайлылык, җайлылык; кулайлылык; *удобство воздушных сообщений* — һава юлларының уңайлылыгы; 2. *перен.* уңайлы шартлар, уңайлылыклар (мәсәлән, квартирда уңай яшәү өчен кирәк булган бөтен нәрсәләр).

**УДОВЛЕТВОРЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет —1. к. удовлетворить 1, 2, 3; 2. канәгатьләнү, канәгатьлек; ләззәт; *испытывать чувство удовлетворения* — канәгатьлек хис итү. ◇ **Требовать удовлетворения.** *устар.* — дуэльгә чакыру.

**УДОВЛЕТВОРЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. канәгатьләнгәнлек, канәгать булу; 2. к. удовлетворение 2.

**УДОВЛЕТВОРЁННЫЙ** — 1. канәгатьләндерелгән; тәэмин ителгән; 2. канәгатьләнгән, канәгать, канәгатьләнүле; *удовлетворённый человек* — канәгать кеше; *удовлетворённый взгляд* — канәгатьләнүле караш.

**УДОВЛЕТВОРИ'ТЕЛЬНО** — 1. *нареч.* канәгатьләнерлек рәвештә, канәгатьләнерлек итеп; 2. *школьн.* уртача (белемне бәяләү билгесе).

**УДОВЛЕТВОРИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — канәгатьләнерлек булу, уртача булу.

**УДОВЛЕТВОРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — канәгатьләнерлек..., канәгатьләндерә торган, уртача; *удовлетворительный ответ* — канәгатьләнерлек җавап.

**УДОВЛЕТВОРИ'ТЬ** *сов.*—1. *офиц.* тәэмин итү; *удовлетворить воинскую часть провиантом* — хәрби частьны азык-төлек белән тәэмин итү; 2. (*возместить понесённый ущерб, обиду и т. п.*) ризалату, канәгатьләндерү; 3. канәгатьләндерү; *удовлетворить потребности населения* — халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерү; 4. җавап бирү, канәгатьләндерү, туры килү; *удовлетворить всем требованиям* — барлык таләпләргә җавап бирү; 5. күңелен күрү, күңелен табу.

**УДОВЛЕТВОРИ'ТЬСЯ** *сов.*— канәгатьләнү, канәгать булу, риза булу, күңел булу.

**УДОВЛЕТВОРЯ'ТЬ** *несов.*— к. удовлетворить.

**УДОВЛЕТВОРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. удовлетвориться; 2. *страд.* канәгатьләндерелү, тәэмин ителү, ризалатылу.

**УДОВО'ЛЬСТВИЕ** *ср.*—1. ләззәт, рәхәт; шатлык; кызык; *испытывать чувство удовольствия* — ләззәт табу; *с удовольствием* — шатлык белән; *мало удовольствия ждать целый час* — сәгать буе көтү бер дә кызык түгел; 2. (*забава, развлечение*) уен-көлке, күңел ачу, хозурлык, рәхәтлек, кәеф-сафа. ◇ **Срывать цветы удовольствия** — к. срывать.

**УДОВО'ЛЬСТВОВАТЬ** *сов. устар.*— канәгатьләндерү, ризалату, күңелен күрү.

**УДОВО'ЛЬСТВОВАТЬСЯ** *сов.*— к. довольствоваться 1.

**УДО'Д** *м.*— һөдһөд, һөдһөд кошы.

**УДО'ДОВЫЙ** — һөдһөд ...-ы; *удодовые гнёзда* — һөдһөд оялары.

**УДО'ДОВЫЕ** *в знач. сущ. ед.* нет, *зоол.*— һөдһөдчәләр (семьялыгы).

**УДО'Й** *м.*—1. савым, сауган сөт; бер сауган сөт; *годовой удой молока* — еллык сөт савымы; 2. саву; *молоко утреннего удоя* — иртән сауган сөт (иртәнге сөт).

**УДО'ЙЛИВОСТЬ** *ж., мн.* нет, *с.-х.*— савымлылык, сөтлелек, сөт бирүчәнлек.

**УДО'ЙЛИВЫЙ** *с.-х.*— савымлы; сөтле, күп сөт бирә торган; *удойливая корова* — сөтле сыер.

**УДО'ЙНИК** *м.*— сөт чиләге (сөт сава торган чиләк).

**УДО'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— савымлылык, сөт бирүчәнлек; сөт биреш; *рост удойности* — сөт биреш арту.

**УДО'ЙНЫЙ** *с.-х.*—1. бер савым ...-ы; бер савудагы; *удойное количество молока* — сөтнең бер савым күләме; 2. саву ...-ы; *удойный период* — саву чоры (сөт бирү чоры); 3. к. удойливый.

**УДОРОЖА'НИЕ** *ср. мн.* нет — кыйммәтләнү, кыйбатлану, бәяләр күтәрелү.

**УДОРОЖА'ТЬ** *несов.*— к. удорожить.

**УДОРОЖА'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. удоро-

житься; 2. *страд.* кыйммәтләндерелү, кыйбатландырылу, бәясе күтәрелү (арттырылу).

**УДОРОЖИ'ТЬ** *сов.*— кыйммәтләндерү, кыйбатландыру, бәя күтәрү, бәя арттыру.

**УДОРОЖИ'ТЬСЯ** *сов.*— кыйммәтләнү, кыйбатлану, бәя күтәрелү, бәя арту.

**УДОСТА'ИВАТЬ, УДОСТО'ИВАТЬ** *несов. книж.*— к. удостоить.

**УДОСТА'ИВАТЬСЯ, УДОСТО'ИВАТЬСЯ** *несов. книж.*— 1. к. удостоиться; 2. *страд.* лаеклы дип табылу, бүләкләнү.

**УДОСТОВЕРЕ'НИЕ** *ср.*—1. *только ед. книж.* к. удостоверить; 2. таныклык, таныклык язуы; *удостоверение личности*— шәхси таныклык; *командировочное удостоверение* — командировка таныклыгы.

**УДОСТОВЕ'РЕННЫЙ** — таныкланган.

**УДОСТОВЕ'РИТЬ** *сов.*— 1. таныклау, таныклык бирү; таныклык бирү, дөреслеген раслау; *удостоверить подпись* — имзаны таныклау; 2. *устар.* (*убедить*) ышандыру, инандыру.

**УДОСТОВЕ'РИТЬСЯ** *сов.*— 1. ышану, инану, тану; *судьи удостоверились в невиновности подсудимого* — судьялар гаепләнүченең гаепсез булуына ышандылар; 2. *устар.* шикләнми башлау; ышану, шик калмау, шик бетү.

**УДОСТОВЕРЯ'ТЬ** *несов.*— к. удостоверить.

**УДОСТОВЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. удостовериться; 2. *страд.* таныклык бирелү; дөреслеге раслану, ышандырылу.

**УДОСТО'ЕННЫЙ** *книж.*— лаеклы, лаек булган; (бүләк) бирелгән, бүләкләнгән, бүләк алган.

**УДОСТО'ИТЬ** *сов.*— лаек дип табу, бүләкләү; (бүләк) бирү; *удостоить Ленинской премии* — Ленин премиясе белән бүләкләү; *удостоить учёной степени доктора* — докторлык гыйльми дәрәҗәсе бирү. ◇ **Удостоить взглядом** —(илтифат итеп) карап ташлау, илтифат күрсәтү. **Удостоить ответом** —(игътибар итеп) җавап бирү.

**УДОСТО'ИТЬСЯ** *сов. книж.*— 1. лаек булу; бүләкләнү; (бүләк, исем) бирелү; *удостоился высшей награды* — югары бүләккә лаек булды; 2. (берәүнең илтифатына) ия булу, ирешү.

**УДОСУ'ЖИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— к. удосужиться.

**УДОСУ'ЖИТЬСЯ** *сов. разг.*—вакыт табу, буш ара табу, мөмкинлек табу.

**УДОЧЕРЕ'НИЕ** *ср. офиц. мн.* нет —кызлыкка алу, балалыкка алу (чит кыз баланы гаиләнең тигез хокуклы әгъзасы итеп рәсмиләштереп асрамага алу).

**УДОЧЕРИ'ТЬ** *сов. офиц.*— кызлыкка алу, балалыкка алу (чит кыз баланы тәрбияләргә алу).

**УДОЧЕРЯ'ТЬ** *несов. офиц.*— к. удочерить.

**УДОЧЕРЯ'ТЬСЯ** *несов. страд. офиц.*— кызлыкка алыну, балалыкка алыну (кыз бала).

**У'ДОЧКА** *ж.*— кармак (сабы белән.)◇ **Закинуть удочку** — к. закинуть. **Поймать или (поддеть) на удочку** *разг. перен.*—алдап серен белү, кармакка эләктерү, тозакка эләктерү. **Попасться на удочку** *разг.*— кармакка кабу, тозакка эләгү (алдану). **Смотать удочки** — к. смотать.

**УДРА'ТЬ** *сов. разг. фам.*— качу, качып китү; таю, сызу, табан ялтырату; *удрать из дому* — өйдән качып китү. ◇ **Удрать штуку (или глупость, дичь)** *разг. фам.*— гаҗәпләнерлек эш эшләп ташлау.

**УДРУЖА'ТЬ** *несов. разг.*— к. удружить.

**УДРУЖИ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. дуслык күрсәтү, яхшылык итү; хезмәт күрсәтү; 2. *перен. ирон.* аю хезмәте күрсәтү, зыян итү.

**УДРУЧА'ТЬ** *несов. разг.* — к. удручить.

**УДРУЧА'ТЬСЯ** *несов.*—к. удручиться.

**УДРУЧЁННЫЙ** — 1. басылган, изелгән, хафаланган; 2. авыр, газаплы, кайгылы, борчулылы.

**УДРУЧИ'ТЬ** *сов.*— 1. хафага төшерү, кайгыга салу, кайгыга төшерү, кайгыга калдыру; *это известие его крайне удручило*— бу хәбәр аны бик нык кайгыга салды; 2. *книж. устар.* борчу, изү; *тяжек сон того, кто горем удручён* (Некрасов) — кайгыдан изелгән кешенең йокысы авыр була (башына кайгы төшкән кешенең йокысы авыр була).

**УДРУЧИ'ТЬСЯ** *сов.*— бик нык борчылу, кайгыга төшү, кайгыга калу, хафага төшү.

**УДУ'МАТЬ** *сов. простореч.*— уйлау, уйлап табу, уйлап чыгару.

**УДУ'МЫВАТЬ** *несов. простореч.*— к. удумать.

**УДУША'ТЬ** *несов. книж.*— к. удушить.

**УДУША'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.*— буылу, буып үтерелү, тончыктырып үтерелү.

**УДУШИ'ТЬ** *сов. книж.*— 1. буу, буып үтерү; томалап үтерү, тончыктыру, тончыктырып үтерү; 2. *перен.* буу; басу, кысу.

**УДУ'ШЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тынчулык, тончыктыргыч булу.

**УДУ'ШЛИВЫЙ** — 1. тынчу, бөркү, тын алырга авыр; *удушливый запах* — тын алырга авыр ис; 2. тончыктыргыч, сулыш юлларын агулый торган; *удушливые газы* — тончыктыргыч газлар.

**УДУ'ШЬЕ** *мн.* нет, *ср.*— буылу, тын бетү.

**УДЬБА'** *ж. мн.* нет, *обл.*— к. уженье.

**УЕДА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. уесть.

**УЕДА'ТЬСЯ** *несов. простореч. страд.*— ашап бетерелү, ашалу.

**УЕДИНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. уединить; 2. (*одиночество*) ялгызлык, ялгыз булу, ялгыз яшәү; аралашмау; *он любил уединение* — ул ялгызлыкны ярата иде; 3. *книж.* (*отдалённое место*) аулак, аулак җир, кешеләрдән ерак җир.

**УЕДИНЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— 1. ялгызлык, читләшкәнлек, аралашмау; 2. аулак булу, кешеләрдән ерак булу.

**УЕДИНЁННЫЙ** —1. аерылган, читләшкән; 2. аралашмый торган; ялгыз; *она вела жизнь уединённую* (Тургенев)— ул кешеләр белән аралашмыйча яши иде; 3. тын, ялгыз, аулак, аулактагы, кешеләрдән ерактагы; *уединённый дом* — аулак йорт.

**УЕДИНИ'ТЬ** *сов.*—(кешеләрдән) читләштерү, аеру; аралашуны өзү.

**УЕДИНИ'ТЬСЯ** *сов.*—(кешеләрдән) читләшү, ераклашу, аралашмый башлау; аулак җиргә китү.

**УЕДИНЯ'ТЬ** *несов.*— к. уединить.

**УЕДИНЯ'ТЬСЯ** *несов.*—1. к. уединиться; 2. *страд.* (кешеләрдән) читләштерелү, ераклаштырылу.

**УЕ'ДЛИВЫЙ** *просторeч.*— интектергеч, тәкать корткыч, теңкә корыткыч, йөдәткеч, аптыраткыч.

**УЕ'ЗД** *м. истор.*— өяз (1. борынгы Русьта — билгеле бер шәһәр тирәсендәге волостьлар; 2. элекке Россиядә һәм районнарга бүлгәнче СССРда — губернаның бер өлеше).

**УЕ'ЗДИТЬ** *сов.*—1. *просторeч.* йөри-йөри такырайту, йөри-йөри шомартып бетерү; *уездить дорогу* —йөри-йөри юлны такырайту; 2. *обл.* җигеп йөреп өшәндерү, җигеп йөреп арыту; 3. җигәргә өйрәтү.

**УЕ'ЗДИТЬСЯ** *сов.*—1. *просторeч.* тапталып шомару, такыраю, такырлану; *дорога уездилась* — юл такырайган; 2. *обл.* җигеп йөрүдән ару, җигеп йөрүдән өшәнү; *уездился конь* — җигеп йөрүдән ат өшәнгән.

**УЕ'ЗДНЫЙ** — 1. *истор.* өяз ...-ы; *уездный город* — өяз шәһәре; 2. *перен. разг. пренебр. устар.* өяз ...-ы; өяз шәһәре ...-ы; өяз шәһәрендәгечә.

**УЕЗЖА'ТЬ** *несов.*— к. уехать.

**УЕ'ЗЖЕННЫЙ** —1. такырайган, тапталган, такыр, шома; 2. (күп йөрүдән) арган, өшәнгән (ат).

**УЕ'ЗЖИВАТЬ** *несов.*—к. уездить.

**УЕ'ЗЖИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. уездиться; 2. *страд.* йөри-йөри такырайтылу.

**УЁМИСТЫЙ** *просторeч.*— сыемлы, күп сыешлы; күп сыйдырышлы; күп әйбер сыя торган.

**УЕ'СТЬ** *сов. просторeч.*—1. ашау, ашап бетерү; 2. *обл.* чагу, тешләү; *уела пчела медведя* (Даль) — аюны бал корты чакты; 3. *перен.* җәфалап бетерү, интектереп бетерү; харап итү, башына җитү, һәлак итү; *уели его придирками* — бәйләнеп аны интектереп бетерделәр; *уело его мотовство* — акча туздыру аны харап итте.

**УЕ'ХАТЬ** *сов.*—(атка, машинага һ. б. утырып) китү, чыгып китү, юлга чыгу. ◇ **Далеко не уедешь** — к. далеко.

**УЖ** I *м* — тузбаш (елан); *обыкновенный уж* — гади тузбаш. ◇ **Извиваться ужом** *перен.*— еландай боргалану, ялагайлану, юмалану. **Ползти ужом** *перен.*— еландай сарылу (ялагайланып берәр нәрсәгә ирешергә тырышу).

**УЖ** II —1. *нареч.* к. уже 1; 2. *разг. усилит. частица* инде, ...-ме тагын? *уж я вас ждала, ждала...*— инде мин сезне көттем, көттем; *уж не тётка ли твоя это натолковала?* (Тургенев)— сиңа моны түтәең сөйләмәдеме тагын? 3. *разг. усилит. частица* ук, инде; ... да; *не так уж плохо* — алай ук начар түгел лә инде; *не знаю, как уж сказать* — ничек әйтергә дә белмим; 4. *нар.-поэт. усилит. частица* инде, ... да инде, менә... да инде; *уж как пал туман на сине море* (песня)— менә дингез өстен томан да басты инде. ◇ **Вот уж** *разг.*— 1. менә бусы, менә бусы инде; *вот уж нет!*— менә бусы инде булмас! 2. менә инде; *вот уж неправда!* (*разг.*)— менә бу инде ялган; **На что уж** — к. что.

**УЖА'К** *м. зоол.*— гади тузбаш.

**УЖА'ЛЕННЫЙ** — корт чаккан; елан чаккан; *как ужаленный* (*вскочил, вскрикнул*) корт чаккандай (сикереп торды, кычкырып җибәрде).

**УЖА'ЛИТЬ** *сов.*— чагу, тешләү (елан, корт һ. б.).

**УЖА'РИВАТЬ** *несов.*— к. ужарить.

**УЖА'РИВАТЬСЯ** *несов. разг.*—1. к. ужариться; 2. *страд.* кыздырылу, кыздырып җиткерелү; кыздырып киметелү.

**УЖА'РИТЬ** *сов. разг.*— 1. (*прожарить*) кыздырып җиткерү, пешкәнче кыздыру; 2. кыздырып киметү, кыздырып киметеп бетерү; *ужарить мясо* — итне кыздырып киметеп бетерү.

**УЖА'РИТЬСЯ** *сов. разг.*—1 (*прожариться*) кызып пешеп җитү, кыздырылып җитү; 2. кыздырудан кимү, кыздырудан кимеп бетү; *мясо ужарилось* — ит кыздырудан кимеп беткән.

**У'ЖАС** *м.*—1. *только ед.* курку, куркыну, кот очу; *навести ужас на кого-н.*—берәүнең котын алу; *его охватил ужас* — аның коты очты; *бежать в ужасе* — куркып качу; 2. *только ед.* фаҗига, котылгысызлык; *почувствовать весь ужас своего положения* — үз хәленең бөтен фаҗигасен сизү; 3. дәһшәт, куркыныч, авырлык; 4. *в знач. сказ. разг.* коточкыч, коточкыч авыр; бик авыр, бик начар; *его положение — прямо ужас* — аның хәле коточкыч авыр; 5. *разг. фам.* менә дигән, бик шәп, исең китәр; бик зәһәр; *такой вкусный, что просто ужас!*— шундый тәмле, исең китәр! 6. *в знач. нареч.* гаять, коточкыч; *ужас далеко* — коточкыч ерак; *ужас как хорошо* — гаять дәрәҗәдә яхшы. ◇ **До ужаса** *разг.*— бик, гаять, чиктән (гадәттән) тыш; *он до ужаса бездушен* — ул гаять рәхимсез (кансыз). **К ужасу** (чьему) *разг.*— бәхетсезлеккә (кызганычка) каршы; *к ужасу моему, я сбился с пути* — бәхетсезлегемә каршы, мин юлны югалттым.

**УЖАСА'ТЬ** *несов.*— к. ужаснуть.

**УЖАСА'ТЬСЯ** *несов.*— к. ужаснуться.

**УЖАСА'ЮЩЕ** *нареч.*— коточкыч, котчыргыч, яман.

**УЖАСА'ЮЩИЙ** — 1. коточкыч, котчыккыч, котын ала торган, курку сала торган; 2. дәһшәтле, йөрәк яргыч, җан әрнеткеч; *ужасающий крик* — дәһшәтле тавыш; 3. бик каты, коточкыч; *ужасающий ветер* — бик каты җил; 4. бик начар, бик яман, бик әшәке; *ужасающий запах* — бик әшәке ис.

**УЖАСНУ'ТЬ** *сов.*— котын алу, котын очыру, йөрәген яру, куркытып җибәрү.

**УЖАСНУ'ТЬСЯ** *сов.*— куркып калу, коты очу, коты чыгу, коты алыну, йөрәге ярылу.

**УЖА'СНО** *нареч.*—1. *разг.* бик, бик нык, бик тә, гаять дәрәҗәдә, чиксез; *я ужасно рад вас видеть* — сезне күрүемә чиксез шатмын; 2. *безл. в знач. сказ.* кот-

очкыч хәл, бик яман.◇ **Он ужасно выглядит** *разг.*— аның бөтенләй төсе киткән.

**УЖА'СНЫЙ** —1. куркыныч, куркынычлы, котчыккыч, коточкыч; *ужасный сон* — куркынычлы төш; *ужасный крик* — коточкыч тавыш; 2. *разг.* коточкыч начар, бик начар; әшәке, яман; *у больного ужасный вид* — авыруның кыяфәте коточкыч начар; *ужасный человек* — бик яман кеше; *ужасная погода* — бик начар һава; 3. *разг. фам.* коточкыч, бик каты, гаять көчле, чиктән тыш; гадәттән тыш; *цены ужасные* — коточкыч бәяләр.

**У'ЖАСТЬ, У'ЖАСТИ** *простореч. обл.*— 1. *в знач. сказ.* коточкыч, котчыккыч, кот очарлык; 2. *нареч.* бик, гаять; котчыккыч; *ужасть холодно* — бик суык.

**УЖА'ТЬ** *сов. простореч.*— кысу, басу, кысып кечерәйтү.

**У'ЖЕ** — таррак.

**УЖЕ'** —1. *нареч.* инде; *он уже не ребёнок*—ул инде бала түгел; 2. *усилит. частица* ук, үк; *не так уже ярко*—бик үк якты түгел.◇**Вот уже (или уж)**—инде, менә инде.

**УЖЕ'ЛИ, УЖЕ'ЛЬ** *нареч. устар. обл.*— к. неужели.

**УЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет— кармак салу, балык каптыру (кармак белән балык тоту).

**У'ЖИВАТЬ** *многокр.*— кармак салгалау, балык тоткалау (кармак белән).

**УЖИВА'ТЬСЯ** *несов.*— к. ужиться.

**УЖИ'ВЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет— тиз ияләшүчәнлек.

**УЖИ'ВЧИВЫЙ** — тиз ияләшүчән, тиз ияләшеп китүчән, тиз үзләшүчән.

**УЖИ'ЛИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. ужилить.

**УЖИ'ЛИВАТЬСЯ** *несов. простореч. страд.*— үзләштерелү, кысып алып калдырылу.

**УЖИ'ЛИТЬ** *сов. простореч.*— кысып алып калу, басып калу, үзләштерү.

**УЖИМА'ТЬ** *несов. простореч.*— к. ужать.

**УЖИМА'ТЬСЯ** *несов. простореч.*—1. (*делать ужимки*) боргалану, боргалану-сыргалану, кыланчыклану; 2. *страд.* кысылу, кысып кечерәйтелү, басылу.

**УЖИ'МКА** *ж.*, чаще *мн.*—кыланыш, боргалану-сыргалану; гримаса (күз кысу, каш сикертү һ. б.).

**У'ЖИН** *м.* — 1. кичке аш, кичке ашау; кичке аш вакыты; (кичке) аш мәҗлесе.

**УЖИ'Н** *обл. м. мн.* нет — урым, урып алынган иген (билгеле бер кырдан урылган ашлыкның күләме).

**У'ЖИНАТЬ** *несов.*— кичке аш ашау, кичкелекне ашау.

**У'ЖИННЫЙ** — кичке аш ...-ы; *ужинный стол* — кичке аш табыны.

**УЖИ'НЫЙ** — к. ужовый.

**УЖИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ияләшү, ияләшеп китү, (күнегеп) яшәргә калу, торып калу, урнашып калу; *он ужился на новом месте*—ул яңа урында торып калды; 2. килешеп тору, килешеп яшәү, тату яшәү, тату тору; *мы с тобой уживёмся* — без синең белән тату яшәрбез; 3. тынышу, тынышып яшәү; *он не ужился с соседями*— ул күршеләре белән тыныша алмады.

**УЖЛИ'** *нареч. простореч.*—к. ужели.

**УЖО'** *нареч. простореч.* — 1. соңрак, соңгарак, бераздан, буш вакыттарак; *приезжайте ужо к нам*— безгә буш вакыттарак килегез; 2. бервакытны, тукта әле; *я вас ужо проучу*—бервакытны мин сезнең кирәгегезне бирермен әле; 3. *(при угрозе)* кирәгеңне бирермен әле! күрсәтермен әле (күрмәгәнеңне)! *ужо я тебя!* — кирәгеңне бирермен әле мин сиңа!

**УЖО'ВНИК** *м. бот.* — вак абага (абагаларның бер төре).

**УЖО'ВЫЙ** — тузбаш ...-ы; *ужовая голова* — тузбаш башы.

**УЖО'НОК, УЖО'НЫШ** *м.* — тузбаш баласы, бала тузбаш.

**У'ЗА'** *ж. с.-х.*—к. прополис.

**УЗАКОНЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *книж.* к. узаконить; 2. *офиц.* рәсми кабул ителгән карар; закон; *сборник узаконений* — законнар җыентыгы.

**УЗАКО'НЕННЫЙ** — законлаштырылган, закон итеп кабул ителгән, рәсмиләштерелгән.

**УЗАКО'НИВАТЬ** *несов.* —к. узаконить.

**УЗАКО'НИВАТЬСЯ** *несов. страд.*— законлаштырылу, рәсмиләштерелү, закон итеп кабул ителү.

**УЗАКО'НИТЬ** *сов.* — 1. законлаштыру, канунлаштыру, закон итеп кабул итү; 2. рәсмиләштерү, законлы итү; *узаконить фактический брак* — булган никахны рәсмиләштерү.

**УЗАКОНЯ'ТЬ** *несов.* — к. узаконить.

**УЗАКОНЯ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — к. узакониваться.

**УЗБЕ'К** *м.* — үзбәк.

**УЗБЕ'КИ** *мн.* — үзбәкләр, үзбәк халкы (Үзбәкстан ССР да яшәүче төрки халык).

**УЗБЕ'КСКИЙ** —1. үзбәк ...-ы; *узбекский язык* — үзбәк теле; 2. Үзбәкстан ... , Үзбәкстан ...-ы; *Узбекская ССР*—Үзбәкстан ССР.

**УЗБЕ'ЧКА** *ж.*— үзбәк хатыны, үзбәк кызы, үзбәк хатын-кызы.

**УЗДА'** *ж.* — 1. йөгән; *надеть узду на лошадь*—атка йөгән кидерү; 2. *перен.* йөгән, тыючы көч, тотып (буйсындырып) торучы көч. ◇ **Держать в узде** *кого-что, перен.*— йөгәнләп (авызлыклап) тоту, буйсындырып тору.

**УЗДЕ'НЬ** *м. истор.*— үздән (комык мирзасы, чиркас мирзасы).

**УЗДЕ'ЧКА** *ж.*—1. йөгән, кечкенә йөгән; 2. *анат.* яры (мәсәлән, тел кереше).

**УЗДЕ'ЧНЫЙ**—йөгән ...-ы; *уздечное кольцо*—йөгән боҗрасы.

**УЗДЦЫ'**: **под уздцы схватить**—йөгәннән тотып алу, авызлык янынан тотып алу.

**УЗДЯНО'Й** — к. уздечный.

**У'ЗЕЛ I** *м.* — 1. төен; төйнәлгән урын, бәйләнгән урын; *узлы на верёвке* — бауның төеннәре; 2. *спец.* узел, үзәк; төен; *железнодорожный узел*—тимер юл узелы; 3. *воен.* төп үзәк пункт, төп терәк пункт, үзәк; *узел обороны* — оборонаның төп терәк пункты; 4. *анат.* төен; *нервный узел* —

нервлар төене; 5 *бот.* буын, буынтык (үсемлек сабагында); *узел кущения* — куаклану буыны; 6. төенчек, төен, бәйләм; *связать вещи в узел* — әйберләрне төенчеккә бәйләү; 7 *(утолщение, бугорок на коже)* төер, төерчек; 8. *тех.* узел, блок (машинаның вак кисәкләрен беркетеп җыелган эрерэре өлешләре). ◇ **Морской узел** — диңгез төене. **Глухой узел**—чияләп бәйләү. **Узел дорог**—юлларның кисешкән урыны. **Узел противоречий** — каршылыклар төене. **Без узлов жить** *простореч. перен.* — кеше бәйләнмәслек итеп эшләү. **Гордиев узел** — Гордий төене (бик четерекле эш). **Рассечь (разрубить) гордиев узел** — Гордий төенен чабып өзү (ягъни читен бер мәсьәләне көч кулланып хәл итү).

**У'ЗЕЛ II** *м. мор.* — узел (корабларның тизлеген үлчәү берәмлеге—1 сәгатькә 1 диңгез миле— 1,852 *км/сәг.)*

**УЗЕЛО'К** *м.* — төенчек; ◇ **Завязать узелок (на память)** — (берәр нәрсәне истән чыгармас өчен) яулык очын төйнәп кую.

**У'ЗЕНЬКИЙ** — тар гына.

**УЗИ'ЛИЩЕ** *ср. старин. ритор.*—зиндан, таш капчык.

**УЗИНА'** *ж. мн.* нет, *обл.* — тар җир, тар урын.

**У'ЗИТЬ** *несов.*—1. к. обуживать; 2. *разг.* тарайтып күрсәтү, нечкә күрсәтү, ябык күрсәтү; *это платье слишком узит её* — бу күлмәк аны бик нечкә күрсәтә.

**У'ЗКИЙ** — 1. тар; инсез; *узкая улица* — тар урам; 2. тар, кысан; кысрык; *узкое платье*—тар күлмәк; 3. *перен.* тар, чикләнгән; *узкие задачи* — чикләнгән бурычлар; *узкая специальнось* — тар белгечлек (тар бер махсус өлкә буенча); 4. *перен.* тар карашлы; (акылы) чамалы, кыска; *узкий человек* — тар карашлы кеше; *узкий ум* — акылы кыска. ◇ **Узкий круг друзей** — иң якын дуслар. **Узкое совещание** — тар киңәшмә (бик аз кешеләр генә катнашкан киңәшмә). **В узком смысле слова** — сүзнең тар мәгънәсендә (алганда). **Узкие гласные** *лингв.*— тар сузыклар (авыз куышының бик тар ачылуы белән әйтелә торган сузыклар). **Узкое место** — к. место.

**УЗКОВЕ'ДОМСТВЕННЫЙ: узковедомственный подход к делу**—эшкә тар ведомствочылык карашыннан чыгып якын килү.

**УЗКОГЛА'ЗЫЙ** — кысык күзле.

**УЗКОГО'РЛЫЙ**—тар авызлы, тар муенлы (мәс., чүлмәк).

**УЗКОГРУ'ДОСТЬ** — тар күкрәклелек, тар түшлелек.

**УЗКОГРУ'ДЫЙ** — тар күкрәкле, тар түшле.

**УЗКОДЕЛЯ'ЧЕСКИЙ**—тар практикларча, эшкуарларча тар; *узкоделяческое отношение к делу*—эшкә тар практикларча караш.

**УЗКОЗА'ДОСТЬ** *спец. ж. мн.* нет — арт саны тар булу (ат, эт һ. б.)

**УЗКОЗА'ДЫЙ** *спец.* — арт саны тар булган, тар арт санлы.

**УЗКОКОЛЕ'ЙКА** *ж. разг.* — тар колеялы тимер юл.

**УЗКОКОЛЕ'ЙНЫЙ** — тар колеялы.

**УЗКОЛИ'СТНЫЙ** *бот.* — тар яфраклы, озынча яфраклы.

**УЗКОЛИ'ЦЫЙ**—тар йөзле, озынча йөзле.

**УЗКОЛО'БИЕ** *ср. мн.* нет, **УЗКОЛО'БОСТЬ** *ж. мн.* нет— 1. тар маңгайлылык; 2. *перен. презрит.* тар маңгайлылык, тар карашлылык, чикләнгәнлек.

**УЗКОЛО'БЫЙ** — 1. тар маңгайлы, маңгае тар...; 2. *перен. презрит.* тар карашлы, тар маңгайлы; *узколобый политикан* —тар карашлы политикан.

**УЗКОПЛЁНОЧНЫЙ: узкоплёночный фотоаппарат**— тар плёнкалы фотоаппарат.

**УЗКОРЯ'ДНЫЙ** *с.-х.*: **узкорядный посев**—тар аралы чәчү, тар рәтле итеп чәчү; **узкорядная сеялка**—тар рәтле чәчкеч (рәт араларын тар итеп чәчә торган).

**У'ЗКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *редко* — тарлык, кысанлык.

**УЗЛИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — күп төенлелек, күп төерлелек, күп төерчеклелек.

**УЗЛИ'СТЫЙ** *спец.* — күп төенле, төенлетөенле, төерчекле.

**УЗЛОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет —төенлелек, төенле булу, төерле булу, төерчекле булу.

**УЗЛОВА'ТЫЙ** — 1. төенле, төерле, төерчекле, тигезсез; *узловатая пряжа* — төерчекле җеп; 2. буынтыклы; төерле-төерле; бүртеп торган, бүртеп чыккан; *узловатые вены*—бүртеп торган кан тамырлары.

**УЗЛОВО'Й**—1. үзәк ..., узел булган, үзәк булган; *узловой пункт* —үзәк пункт; 2. *перен.* төп, нигез, үзәк; *узловой вопрос*—үзәк мәсьәлә; 3. төенле, төенсыман, төерчекле; буынлы, буынлы-буынлы, буынтыклы; *узловое сплетение нервов* (анат.)— нервларның буынлы-буынлы төенләнеше. ◇ **Узловая станция** *ж.-д.*—үзәк станция (тимер юлда).

**УЗЛОВЯЗА'ТЕЛЬ** *ж. тех.*—җеп ялгагыч, җеп бәйләгеч.

**УЗЛОУЛОВИ'ТЕЛЬ** *м. тех.* — төердән чистарткыч (кәгазь измәсен чит кисәкчекләрдән арындыру машинасы).

**УЗНАВА'ТЬ** *несов.* — к. узнать.

**УЗНАВА'ТЬСЯ** *несов.* — белену, танылу, танып белену.

**УЗНА'ТЬ** *сов.* — 1. (күреп) тану, танып алу; *еле узнал старого друга* – иске дусымны көчкә таныдым; 2. белү, белеп алу; аңлау, төшену; *узнать чей-н. характер*—берәүнең холкын белеп алу; 3. белү, белешү, сорап белү, сорашып белү; *узнайте, дома ли он*—ул өйдәме-юкмы, белешегез; 4. ишетү, ишетеп белү; *узнать все новости по радио* — бөтен яңа хәбәрләрне радиодан ишетеп белү. ◇ **Узнать нужду**—нужа күрү, нужа тату. **У меня узнает, как не слушаться старших** — олыларны тыңламауның нәрсә икәнен күрсәтермен мин аңа.

**УЗНА'ТЬСЯ** *сов. разг. редко* — белену, танылу.

**УЗНИ'К** *м.*, **УЗНИ'ЦА** *ж. книж. ритор. устар.*—тоткын, мәхбүс.

**У'ЗНИЧЕСКИЙ** *книж.*—тоткын ...-ы; тот-

кыннар ...-ы; тоткынлык ...-ы; *узническая жизнь* — тоткыннар тормышы.

**У'ЗНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — тоткынлык, мәхбүслек, ябылуда булу.

**УЗО'Р** *м.* — бизәк, нәкыш; парча; *узор ткани* — тукыманың бизәге. ◇ **Узоры для вышивания** — чигеш үрнәкләре.

**УЗО'РНЫЙ** — 1. бизәк ...-ы; *узорные линии* — бизәк сызыклары; 2. к. узорчатый.

**УЗО'РЧАТОСТЬ** *ж. мн.* нет — бизәклелек, бизәкләнгән булу, нәкышле булу.

**УЗО'РЧАТЫЙ** — бизәкле, нәкышле, парчалы.

**У'ЗОСТЬ** *ж.* — 1. тарлык, кысрыклык; инсезлек; *узость улиц* — урамнарның тарлыгы; 2. тарлык, кысанлык; *узость платья* — күлмәкнең кысанлыгы; 3. *перен.* тарлык, чикләнгәнлек, берьяклылык; 4. *воен.* тар җир, тарлавык, тар юл.

**УЗРЕ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. күрү, күреп алу; 2. *перен.* ...дип аңлау, ... дип белү; *он узрел в этом обиду* — ул моны кимсетү дип аңлады.

**УЗУА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — гадәти, гадәттәге.

**УЗУРПА'ТОР** *м. книж.* — узурпатор (властьны законсыз рәвештә үз кулына алган кеше).

**УЗУРПА'ТОРСКИЙ** *книж.* — узурпатор ...-ы; узурпаторлык ...-ы; *узурпаторские действия* — узурпаторлык хәрәкәтләре.

**УЗУРПА'ТОРСТВО** *ср.* — узурпаторлык, узурпация ясау, властьны көч белән тартып алу.

**УЗУРПА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. узурпаторство.

**УЗУРПИ'РОВАТЬ** *сов. и несов., книж.* — узурпация ясау, узурпацияләү, законсыз рәвештә тартып алу (властьны, хокукны).

**УЗУРПИ'РОВАТЬСЯ** *несов страд. книж.* — узурпацияләнү, узурпация ясалу, законсыз тартып алыну.

**У'ЗУС** *м. книж. право* — гадәт.

**У'ЗЫ** *ед. нет* — 1. *старин. (цепи, оковы)* богау, чылбыр; 2. *перен.* золым, изү, богау; *борьба за освобождение от империалистических уз* — империализм богауларыннан котылу өчен көрәш; 3. *перен. книж.* бәйләнеш, бәйләнеш, якынлык; *братские узы* — туганлык бәйләнешләре.

**УЙГУ'Р** *м.* — уйгур.

**УЙГУ'РКА** *ж.* — уйгур хатыны, уйгур кызы, уйгур хатын-кызы.

**УЙГУ'РСКИЙ** — уйгур ...-ы; *уйгурский язык* — уйгур теле.

**УЙГУ'РЫ** *мн.* — уйгурлар, уйгур халкы (Көнчыгыш Казахстанда һәм Көнбатыш Кытайның Синцзян өлкәсендә яшәүче төрки халык).

**У'ЙМА** *ж. мн.* нет, *разг.* — чиксез күп; хисапсыз күп, дөнья, бинибая күп.

**У'ЙМИЩА** *ж. мн.* нет, *разг.* — к. уйма.

**УЙТИ'** *сов.* — 1. китү; чыгып китү, китеп бару; *я ушёл вместе с ним* — мин аның белән бергә киттем; *самолёт ушёл на север* — самолёт төньякка китте; 2. китү, китеп югалу; *туча ушла за горизонт* — болыт офык артына китеп югалды; 3. китеп бетү, чыгып бетү; *весь товар ушёл из склада* — бөтен товар складтан чыгып бетте; 4. китү, ташлап китү; *жена ушла от него* — хатыны аны ташлап китте; 5. *(убежать, скрыться)* качу, качып котылу, качып китү; *уйти из тюрьмы* — төрмәдән качу; *уйти от зверя* — ерткыч җанвардан качып котылу; 6. *устар. (избежать, отделаться)* китеп котылу, котылып калу, ычкыну; *ты от меня не уйдёшь* — син миннән китеп котыла алмассың; 7. китү, ташлау, чыгу (эшләми башлау); *уйти со сцены* — сәхнәдән китү; *уйти со службы* — хезмәтне ташлау; *уйти от политики* — политиканы ташлау (политикадан читләшү); 8. бетү, югалу, калмау; *невесты не уйдут* — кәләш бетмәс; *силы ушли* — көч бетте; 9. *разг. (израсходоваться)* китү, тотылу, сарыф ителү, бетү; *за этот месяц ушло много денег* — бу айда акча күп тотылды; 10. *разг.* тотылып бетү, китеп бетү; *на костюм уйдёт весь остаток материи* — калган материя костюмга бөтенләй китеп бетәчәк; 11. керү, батып керү; *свая ушла в землю на метр* — субай җиргә бер метр керде; 12. бирелү; бату, чуму; *уйти в науку* — фәнгә бирелү; *уйти с головой в работу* — башы-аягы белән эшкә чуму; *уйти в размышления* — уйга бату, уйга чуму; 13. (эшкә) китү, күчү; *уйти на работу по другому ведомству* — башка ведомствога эшкә күчү; 14. *разг.* үтү, узу; үтеп китү, узып китү (гомер); *молодость ушла* — яшьлек үтеп китте; 15. *разг.* ташу, ташып чыгу, ташып бетү, ташып түгелү; *молоко ушло* — сөт ташып чыкты; *шампанское ушло* — шампанский ташып түгелде; *самовар ушёл* — самовар ташып бетте; 16. *устар.* узу, уздыру, узып китү, алга чыгу; *ученик ушёл от своих сверстников* — укучы яшьтәшләреннән уздырды; 17. *(о часах)* алга китү; 18. сыю, керү; *в самовар уйдёт ведро воды* — самоварга бер чиләк су сыяр. ◇ **Далеко не уйдёшь** — к. далеко. **Уйти вперёд** *перен.* — (башкалардан) уздыру, алга китү; узып китү. **Уйти далеко** *(в чём, от кого-чего), перен.* — (берәр эштә) бик нык алга китү, бик ерак китү. (башка берәү белән чагыштырганда зур уңыш казану). **Уйти ни с чем** — к. что. **Уйти из жизни (из мира сего)** *ритор.* — дөньядан китү, дөнья кую (үлү). **Уйти от кого-н.** *ритор.* — ташлап китү (үлү). **Уйти от хозяйства** — хуҗалык эшләре белән шөгыльләнми башлау. **Уйти от забот** — кайгыртмый башлау (мәсәлән, дөнья кайгысын). **Уйти от жизни** (от мира) — дөнья эшләреннән кул селтәү. **Уйти от религии** — дингә ышанмый башлау. **Не уйдёшь суда мирского** — халык хөкеменнән кача алмассың. **Уйти из мира** — монастырьга китү (монах булу). **Уйти в себя** — уйга чуму, уйларга бирелү. **Лук ушёл в стрелки** — суган көпшәгә китте.

**УКА'З** *м.* — 1. указ; *Указ Президиума Верховного Совета СССР* — СССР Верховный Советы Президиумының Указы; 2. *ус-*

*тар.* боерык, әмер, фәрман, кушу; *по указу его императорского величества* — император галиҗәнапләренең әмере буенча (элеккеге суд карарларының башланышы). ◇ **Ты мне не указ** — синең сүзең миңа закон түгел.

**УКАЗА'НИЕ** *ср.*— 1. к. указать 1, 2; 2. күрсәтмә, киңәш; *по указанию из центра* — үзәктән килгән күрсәтмә буенча.

**УКА'ЗАННЫЙ** — 1. күрсәтелгән, күрсәтеп бирелгән; 2. билгеләнгән, билгеләп куелган; *явиться в указанный срок* — билгеләнгән вакытка килеп җитү; 3. к. вышеуказанный.

**УКАЗА'ТЕЛЬ** *м.*— 1. күрсәткеч; язу; *указатель дорог* — юл күрсәткеч; 2. белешмә, белешмәлек; *железнодорожный указатель* — тимер юл белешмәсе (тимер юлга караган төрле мәгълүматлар җыелган белешмә китап); 3. күрсәткеч, исемлек; *библиографический указатель* — библиографик күрсәткеч (китап яки исемлек); *указатель имён* — исемнәр күрсәткече.

**УКАЗА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. күрсәтә торган, күрсәтүче, күрсәткеч...; *указательная стрелка* — күрсәткеч ук; 2. *грам.* күрсәтү...-ы; *указательное местоимение* — күрсәтү алмашлыгы. ◇ **Указательный палец** (перст) — имән бармак.

**УКАЗА'ТЬ** *сов.*— 1. күрсәтү, күргәзү, күрсәтеп бирү; *указать дорогу* — юл күрсәтү; *указать лучший метод* — иң яхшы алымны күрсәтеп бирү; 2. күрсәтү, төртеп күрсәтү; ишарә итү; *указать пальцем* (на кого-н.) — (берәүгә) бармак белән төртеп күрсәтү; 3. күрсәтү, күрсәтеп үтү; *указать на недостатки в работе* — эштәге кимчелекләрне күрсәтеп үтү; 4. күрсәтеп бирү, өйрәтү, аңлатып бирү; *указать, как вести работу* — ничек эшләү турында күрсәтеп бирү; 5. *устар., разг.* (*приказать*) боеру, әмер бирү, эш кушу; *в своём доме ему никто не может указать* — үз өендә аңа беркем эш куша алмый. ◇ **Указать двери** (на дверь) — куып чыгару.

**УКА'ЗКА** *ж.*— 1. күрсәткеч, күрсәткеч таяк; 2. *разг. неодобр.* күрсәтү, күрсәтмә; *делать всё по указке* — күрсәткәнне генә эшләү.

**УКА'ЗНЫЙ** *офиц. устар.*— 1. указ...-ы; указлар...-ы; *указная книга* — указлар китабы; 2. закон белән куелган, закон белән билгеләнгән, законлы; указлы; *указный мулла* — указлы мулла.

**УКА'ЗЧИК** *м.*, **УКА'ЗЧИЦА** *ж. разг.*— акыл өйрәтүче, күрсәтеп торучы, өйрәтеп торучы.

**УКА'ЗЫВАТЬ** *несов.*— к. указать.

**УКА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.*— күрсәтелү.

**УКА'ЛЫВАТЬ** *несов.*— 1. к. уколоть; 2. чәнечкәләү.

**УКА'ЛЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. уколоться.

**УКА'ПАТЬ** *сов. разг.*— тамызып бетерү, тамызып пычрату, тамызып пычратып бетерү.

**УКА'ПАТЬСЯ** *сов. разг.*— (берәр нәрсә) тамызып өстенне пычратып бетерү.

**УКА'ПЫВАТЬ** *несов.*— к. укапать.

**УКА'ПЫВАТЬСЯ** *несов.*— к. укапаться.

**УКАРАУ'ЛИТЬ** *сов. разг.*— к. устеречь.

**УКА'Т** *м. мн.* нет, *простореч. спец.*— к. укатка 1.

**УКАТА'ТЬ** *сов.*— 1. (берәр авыр нәрсә тәгәрәтеп яки күп йөреп) такырайту, тигезләү, такырайтып бетерү; *укатать дорогу* — юлны такырайтып бетерү; 2. *простореч. спец.* тыгыз итеп басу (мәсәлән, туланы, киез итекне); 3. *обл.* чаптырып арыту, чаптырып йончыту; *укатать лошадь* — атны чаптырып йончыту. ◇ **Укатали сивку крутые горки** — кешене тәмам җыкка сабыштырдылар, егетне дөнья мәшәкате тәмам эштән чыгарды.

**УКАТА'ТЬСЯ** *сов.*— 1. (күп йөрүдән) такыраю, тигезләнү, такыраеп бетү; *дорога укаталась* — юл такыраеп беткән; 2. *простореч. спец.* тыгыз басылу (киез итек, тула һ. б.).

**УКАТИ'ТЬ** *сов.*— 1. тәгәрәтеп алып китү; *укатить обруч* — кыршауны тәгәрәтеп алып китү; 2. *разг.* (*уехать*) китү, китеп бару.

**УКАТИ'ТЬСЯ** *сов.*— тәгәрәп китү, тәгәрәп кереп китү.

**УКА'ТКА** *ж.*— 1. к. укатать 1, 2; 2. *спец.* тәгәрәткеч, юл тигезләгеч.

**УКАТНУ'ТЬ** *сов. однокр., разг. фам.*— к. укатить.

**УКА'ТЧИК** *м. спец.*— 1. юл тигезләүче; 2. басучы, тыгызлап басучы (киез итекне, туланы һ. б.).

**УКА'ТЫВАТЬ** I *несов.*— к. укатать.

**УКА'ТЫВАТЬ** II *несов.*— к. укатить.

**УКА'ТЫВАТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. укататься; 2. *страд.* такырайтылу, шомартылу (мәсәлән, юл); 3. *страд.* чаптырып арытылу, чаптырып өшәндерелү.

**УКА'ТЫВАТЬСЯ** II *несов.*— 1. к. укатиться; 2. *страд.* тәгәрәтелү, тәгәрәтеп алып кителү, тәгәрәтеп алып барылу.

**У'КАТЬ** *несов. простореч.*— ууу дип кычкыру, уылдау.

**УКА'ЧАННЫЙ** — 1. тирбәтелгән, тирбәтеп йоклатылган; 2. чайкалудан йокымсыраган, чайкалудан күңеле болганган.

**УКАЧА'ТЬ** *сов.*— 1. тирбәтү, тирбәтеп йоклату; *укачать ребёнка на руках* — баланы кулда тирбәтеп йоклату; 2. чайкалдырып күңел болгандыру; чайкалдырып йокымсырату (мәсәлән, пароходта).

**УКАЧА'ТЬСЯ** *сов. разг.*— чайкалудан йокымсырау; чайкалудан күңел болгану (мәсәлән, пароходта).

**УКА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. укачать.

**УКА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. *разг.* к. укачаться; 2. *страд.* тирбәтелү, тирбәтеп йоклатылу.

**УКИПА'ТЬ** *несов. разг.*— к. укипеть.

**УКИПЕ'ТЬ** *сов. разг.*— 1. кайнап азаю, кайнап кимү, кайнап бетү; *вода укипела наполовину* — суның яртысы кайнап беткән; 2. (аш) пешеп җитү, кайнап пешеп җитү, өлгерү.

**УКИСА'ТЬ** *несов. разг.*— к. укиснуть.

**УКИ'СНУТЬ** *сов. разг.*— әчеп җитү, тозланып җитү (мәсәлән, кәбестә).

**УКЛА'Д** *м.*— 1. (күптән урнашкан) тормыш рәвеше, уклад; *общественно-экономический уклад* — иҗтимагый-экономик уклад; 2. *спец.* корыч (пычак, кылыч һ. б. ясау өчен).

**УКЛАДА'ТЬ** *несов. простореч. обл.*— к. укладывать.

**УКЛА'ДИСТЫЙ** *простореч.*— күп сыешлы; зур; *укладистая корзина*— күп сыешлы кәрзин.

**УКЛА'ДКА** *ж.*— 1. к. уложить 3, 4, 5, 6; 2. *обл.* кечкенә сандык, юл сандыгы.

**УКЛА'ДОЧНЫЙ** — 1. салу...-ы; өю...-ы; төшәү...-ы, җәю...-ы; *укладочные принадлежности* — төшәү әйберләре; 2. *обл.* кечкенә сандык...-ы; *укладочная крышка* — кечкенә сандык капкачы.

**УКЛА'ДЧИК** *м.*, **УКЛА'ДЧИЦА** *ж. спец.*— салучы; өюче; куючы; *укладчик путей* — юл салучы; *укладчик скирда* — эскерт куючы.

**УКЛА'ДЫВАТЬ** *несов.*— к. уложить 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7.

**УКЛА'ДЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. уложиться, улечься 1, 2, 3; 2. *страд.* яткырылу, йокларга яткырылу; 3. *страд.* урнаштырылу, салыну, салып куелу; 4. *страд.* түшәлү, җәелү; салыну, өелү.

**УКЛА'НЯТЬ** *сов. обл.*— ялынып күндерү, үтенеп күндерү, ялварып күндерү.

**УКЛА'СТЬ** *сов. простореч.*— к. уложить 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7.

**УКЛА'СТЬСЯ** *сов. простореч.*— к. уложиться 1, 2, 3, 4.

**УКЛЕ'ЕЧНЫЙ** — җилембалык...-ы; *уклеечный крючок* — җилембалык кармагы.

**УКЛЕ'ИВАТЬ** *несов. разг.*— к. уклеить.

**УКЛЕ'ИВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. уклеиться; 2. *страд.* ябыштырылу, ябыштырып сыйдырылу.

**УКЛЕИ'ТЬ** *сов. разг.*— ябыштыру, ябыштырып чыгу, ябыштырып бетерү; ябыштырып сыйдырып бетерү.

**УКЛЕИ'ТЬСЯ** *сов. разг.*— ябыштырылып сыеп бетү (мәсәлән, бер биткә).

**УКЛЕ'ЙКА** *ж.*— җилембалык, меле.

**УКЛО'Н** *м.*— 1. авыш(лык), авышканлык, янтайганлык; кыйшаю, янтаю, авышу; *уклон мачты* — мачтаның янтаюы; 2. сөзәклек, сөзәк җир; 3. авышлык; юнәлеш; *школа с техническим уклоном* — техник юнәлешле мәктәп (ягъни төп гомуми белем өстенә тагын техник юнәлеш тә бирә торган мәктәп); 4. *перен.* тайпылыш; *правый уклон* — уң тайпылыш; *левый уклон* — сул тайпылыш.

**УКЛОНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. *книж.* к. уклонить; 2. к. уклониться; *уклонение от удара* — сугудан читкә тайпылу; *уклонение от темы* — темадан читкә чыгу; *уклонение от обязанностей* — вазифаларын үтәүдән баш тарту.

**УКЛОНИ'ЗМ** *м. мн.*, нет, *полит.*— тайпылыш, тайпылыш политикасы.

**УКЛОНИ'СТ** *м.*, **УКЛОНИ'СТКА** *ж. полит.*— тайпылышчы, тайпылучы (карашларда, политикада).

**УКЛОНИ'СТСКИЙ** *полит.*— тайпылыш...-ы; тайпылышчы..., тайпылучы; *уклонистские элементы* — тайпылышчы элементлар.

**УКЛОНИ'ТЬ** *сов. книж.*— читкә этәрү, янтайту, кыйшайту.

**УКЛОНИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. тайпылу, тайпылып калу; *уклониться от удара* — сугудан тайпылып калу; 2. (читкә) кереп китү; борылу; авышу; *уклонились в сторону и попали в болота*— юлдан читкә кереп киттек тә сазлыкка эләктек; *дорога уклонилась вправо* — юл уңга борылды; 3. *перен.* читкә китү, читләшү, читкә чыгу, ераклашу (темадан); 4. *перен.* качу, качарга тырышу; баш тарту, йөз чөерү; *уклониться от прямого ответа* — туры җавап бирүдән качу.

**УКЛО'ННЫЙ** *спец.*: **уклонные знаки** *ж.-д.*— авышлык билгеләре (тимер юлда).

**УКЛО'НЧИВО** *нареч.*—икеле-микеле итеп, икеләнеп.

**УКЛО'НЧИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *устар.* йомшаклык, юл куючан булу; күндәмлек; 2. икеле-микеле булу, туры булмау; *уклончивость ответа* — җавапның туры булмавы (туры җавап бирмәү).

**УКЛО'НЧИВЫЙ** — 1. *устар.* йомшак, юаш, юл куючан, күндәм; 2. икеле-микеле, туры әйтелмәгән; ачык әйтелмәгән; *уклончивый ответ* — икеле-микеле җавап. ◇ **Уклончивая политика** — аумакай; политика.

**УКЛОНЯ'ТЬ** *несов. книж.*— к. уклонить.

**УКЛОНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. уклониться; 2. *страд. книж.* читкә этәрелү, кыйшайтылу, янтайтылу.

**УКЛЮ'ЖИЙ** *разг. редко* — житез, өлгер; төз, килешле (буй-сыны).

**УКЛЮ'ЧИНА** *ж.*— ишкәк чөе (көймәдә ишкәк беркетелә торган урын).

**УКО'ВКА** *ж. мн.* нет, *тех.*— чүкеп нечкәртү, чүкеп юкарту.

**УКОВЫ'ЛИВАТЬ** *несов. разг. фам.*— к. уковылять.

**УКОВЫЛЯ'ТЬ** *сов. разг. фам.*— аксаклап китү, чатанлап китү, тыйтаклап китү, аксаклап китеп бару, чатанлап китеп бару.

**УКОВЫРНУ'ТЬ** *сов. простореч.*— казып чыгару, чокып алу, казып куптарып алу.

**УКО'КАТЬ** *сов. простореч. вульг.*— к. укокошить.

**УКОКО'ШИТЬ** *сов. простореч.*— үтерү, бәреп үтерү, сугып үтерү.

**УКО'Л** *м.*—1. к. уколоть 1, 2; *укол иголкой* — энә белән чәнчү (кадау); 2. *воен.* сөңге белән кадау; 3. *мед.* укол, укол кадау; *назначить больному уколы* — авыруга укол билгеләү; 4. *разг.* укол урыны, укол кадаган төш; *укол болит* — укол кадаган төш авырта; 5. *перен.* чәнчү, тию; рәнҗетү; *уколы самолюбию* — кешенең шәхесенә тию.

**УКОЛА'ЧИВАТЬ** *несов. простореч.*— к. уколотить.

**УКОЛОТИ'ТЬ** *сов. простореч.*— 1. таптап тыгызлау, төеп тыгызлау; дыңгычлау; *уколотить землю* — җирне төеп тыгызлау; 2. кагып бетерү; бик күп кагу; *уколотить дверь гвоздями* — ишеккә бик күп кадак кагу.

**УКОЛО'ТЬ** *сов.*— 1. чәнчү, кадау; (әйбер) кадалу; ***уколол руку иглой*** — кулыма энә кададым; 2. *перен.* чәнчү, чәнчеп әйтү; төрттереп әйтү, тию; ***уколоть чьё-н. самолюбие*** — берәүнең намусына тию; 3. *простореч.* (бик күп әйбер) кадап чыгу, кадап бетерү.

**УКОЛО'ТЬСЯ** *сов.*— кадалу, чәнчелү (тәнгә энә керү һ. б. ш. кебек).

**УКОЛУПНУ'ТЬ** *сов. простореч.*— куптару, куптарып алу.

**УКОМПЛЕКТОВА'НИЕ** *ср.*— 1. к. укомплектовать; 2. *воен.* яңа гаскәр, яңа гаскәри частьлар.

**УКОМПЛЕКТО'ВАННЫЙ** — 1. тулыландырылган, комплектландырылган, комплектлаштырылган; 2. тулы, тулы составлы, тулыланган.

**УКОМПЛЕКТОВА'ТЬ** *сов.*— 1. тулыландыру, тиешле санга җиткерү; комплектын тутыру, комплектлаштыру; 2. (кирәк әйберләр белән) тәэмин итү.

**УКОМПЛЕКТОВА'ТЬСЯ** *сов.*— тулылану, комплекты тулу, комплектлану, тиешле санга җитү.

**УКОМПЛЕКТО'ВЫВАТЬ** *несов.*— к. укомплектовать.

**УКОМПЛЕКТО'ВЫВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. укомплектоваться; 2. *страд.* тулыландырылу, комплекты тутырылу; комплектлаштырылу, тиешле санга җиткерелү.

**УКО'Р** *м.*— шелтә, шелтәләү, әрләү; үпкә; ***посмотреть с укором*** — шелтә белән карау. ◇ **Укоры совести** — вөҗдан газабы (ачыну).

**УКОРА'ЧИВАТЬ** *несов.*— к. укоротить.

**УКОРА'ЧИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. укоротиться; 2. *страд.* кыскартылу.

**УКОРЕНИ'ТЬ** *сов.*— 1. *с.-х.* тамырландыру, төпләндерү; тамыр җәйдерү; 2. *перен.* ныклап урнаштыру, ныгыту; сеңдерү, гадәтләштерү.

**УКОРЕНИ'ТЬСЯ** *сов.*—1. *с.-х.* тамырлану, төпләнү; тамыр җәю; 2. *перен.* тамыр җәю, ныгу, төпләнү, ныклап урнашу, гадәт булып китү.

**УКОРЕНЯ'ТЬ** *несов.*— к. укоренить.

**УКОРЕНЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. укорениться; 2. *страд.* ныклап урнаштырылу, ныгытылу.

**УКОРИ'ЗНА** *ж.*— к. укор.

**УКОРИ'ЗНЕННО** *нареч.*— шелтәле рәвештә, шелтәләп, шелтә белән, шелтәле итеп, үпкәләп.

**УКОРИ'ЗНЕННЫЙ** — шелтәле, үпкәле, әрләү...-ы; шелтәләү...-ы; ***укоризненные слова*** — шелтәләү сүзләре.

**УКОРИ'ТЕЛЬ** *м. книж.*— шелтәләүче, әрләүче.

**УКОРИ'ТЕЛЬНО** *нареч.*—к. укоризненно.

**УКОРИ'ТЕЛЬНЫЙ** — к. укоризненный.

**УКОРИ'ТЬ** *сов.*— шелтәләү, әрләү, битәрләү, гаепләү.

**УКОРОТИ'ТЬ** *сов.*— кыскарту, кыскарак итү.

**УКОРОТИ'ТЬСЯ** *сов.*— кыскару, кыскарып калу.

**УКОРЯ'ТЬ** *несов.*— к. укорить.

**УКО'С** I *м., с.-х.*—чабым, чабылган печән.

**УКОС** II *м.*, **УКО'СИНА** *ж. тех.*— терәк, терәү.

**УКО'СНЫЙ** *с.-х.*— чабулык...-ы; чабынлык...-ы; печәнлек...-ы; ***укосные угодья*** — печәнлек җирләр. ◇ **Укосная продукция** — чабылган печән.

**УКОЧЕВА'ТЬ** *сов.*— күчеп китү.

**УКОЧЁВЫВАТЬ** *несов.* — к. укочевать.

**УКРА'ДКОЙ** *нареч.* — 1. яшертен, астыртын, урлтын, яшеренеп кенә, качып-посып кына; кешегә сиздермичә, белдермичә; ***мальчик украдкой про рался в сад*** — малай качып-посып кына бакчага керде; ***девочка украдкой утерла слёзы*** — кызчык кешегә сиздермичә генә күз яшьләрен сөртте; ***взглянуть украдкой*** — астыртын гына карап алу; 2. бик азга гына, аз гына вакытка, кыска гына вакытка; ***вот солнце глянуло украдкой*** (Некрасов) — менә кыска гына вакытка кояш карап алды.

**УКРА'ЕК** *м. обл.* — кырый, кырпу, кайма.

**УКРА'ИНА** I *ж. старин.* — чик өлкәләр.

**УКРА'ИНА** II *ж.* — Украина, Украина ССР; ***Советская Украина*** — Советлар Украинасы.

**УКРАИНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — к. украинизировать.

**УКРАИНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — украинлаштыру (украин телен һәм культурасын урнаштыру).

**УКРАИНИЗИ РОВАТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов.* украинлашу, украинлашып бетү; 2. *страд. несов.* украинлаштырылу.

**УКРАИ'НКА** I *ж.* — украин хатыны, украин кызы, украинлы хатын-кыз.

**УКРАИ'НКА** II *ж. мн.*, нет, *с.-х.* — украин бодае (шул исемдәге сортлы ужым бодае).

**УКРА'ИННЫЙ** *старин.* — чик өлкәләрдәге.

**УКРАИ'НСКИЙ** — украин ...-ы; украиннар ...-ы; Украина ...-ы; ***украинский язык*** — украин теле.

**УКРАИ'НЦЫ** *мн. (ед.* украинец). — украиннар (Украина ССРның төп халкын тәшкил итүче славян халкы).

**УКРА'СИТЬ** *сов.* — 1. бизәү, матурлау, зиннәтләү; ***украсить дома флагами*** — өйләрне флаглар белән бизәү; 2. *перен.* бизәкләү, матурлау; ***украсить речь изречениями*** — сөйләмне тапкыр тәгъбирләр белән бизәкләү; 3. *перен.* бизәү, матурайту, ямьләндерү; ***любовь украсила жизнь*** — мәхәббәт тормышны ямьләндерде.

**УКРА'СИТЬСЯ** *сов.* — бизәлү, ямьләнү, матураю, матурлану, зиннәтләнү.

**УКРА'СТЬ** *сов.* — урлау, урлап китү, урлап алу, урлап алып китү.

**УКРАША'ТЕЛЬ** *м. книж. неодобр.* — артык бизәкләүче, артык бизәүче.

**УКРАША'ТЕЛЬСКИЙ** *книж. неодобр.* — артык бизәү ...-ы; артык бизәкләү ...-ы; ***украшательская тенденция*** — артык бизәү тенденциясе.

**УКРАША'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*

16

*неодобр.* — артык бизәкләүчелек (тышкы бизәкләргә артык зур әһәмият бирү).

**УКРАША'ТЬ** *несов.* — к. украсить.

**УКРАША'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. украситься; 2. *страд.* матурайтылу, бизәкләнү, зиннәтләндерелү, ямьләндерелү.

**УКРАШЕ'НИЕ** *ср.*—1. *только ед.* к. украсить; 2. бизәк, зиннәт, уенчык; *ёлочные украшения* — ёлка уенчыклары. ◇ **Она была лучшим украшением города** — шәһәрнең иң гүзәл хатыны иде ул.

**УКРЕ'ПА** *ж. обл., устар., нар.-поэт.* — 1. *только ед.* к. укрепить 1; 2. ныгыткыч, беркеткеч; ныгыта торган нәрсә.

**УКРЕПИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — ныгыту ...-ы; *укрепительные работы* — ныгыту эшләре.

**УКРЕПИ'ТЬ** *сов.* — 1. ныгыту, ныгайту, ныгытып кую; беркетү, беркетеп кую; *укрепить плотину* — буаны ныгыту; 2. ныклап борып кую; *укрепить гайку* — гайканы ныклап борып кую; 3. *воен.* (хәрби яктан) ныгыту, ныгытма төзү; 4. (сәламәтлекне) ныгыту, яхшырту; *укрепить нервы* — (какшаган) нервларны ныгыту; 5. ныгыту, көчәйтү, куәтләндерү; *укрепить лагерь мира и демократии* — тынычлык һәм демократия лагерен ныгыту; 6. *офиц. устар. (передать в собственность)* милек багышлау, милек итеп бирү (рәсми акт белән).

**УКРЕПИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ныгу, ныгаю, берегү; *берег укрепился* — яр ныгыды; 2. *воен.* ныгып урнашу, ныгып алу, ныгытма төзү; *неприятель укрепился в лесу* — дошман урманда ныгып урнашкан; 3. (сәламәтлек) ныгу, яхшыру; *нервы укрепились* — нервлар ныгыды; 4. ныгу, көчәю; *дружба укрепилась* — дуслык ныгыды; *дисциплина укрепилась* — дисциплина ныгыды.

**УКРЕПЛЕ'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. укрепить; 2. *только ед.* к. укрепиться; 3. *воен.* ныгытма; *долговременные укрепления* — озак вакытлы ныгытмалар. 4. корылма; *береговые укрепления* — яр буе корылмалары.

**УКРЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — к. укрепить.

**УКРЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. укрепиться; 2. *страд.* ныгытылу, беркетелү.

**УКРО'МНОСТЬ** *ж. мн.* нет — аулаклык, тынлык.

**УКРО'МНЫЙ** — аулак, тын.

**УКРО'П** *м. мн.* нет — укроп (аш тәмләткеч үлән).

**УКРО'ПНЫЙ** — укроп ...-ы; *укропный запах* — укроп исе; *укропное масло* — укроп мае.

**УКРОТИ'ТЕЛЬ** *м.*, **УКРОТИ'ТЕЛЬНИЦА** *ж.* — кулга өйрәтүче, буйсындыручы (ерткыч җанварларны).

**УКРОТИ'ТЬ** *сов.* — 1. өйрәтү, кулга өйрәтү, буйсындыру; *укротить дикого зверя* — ерткыч хайванны кулга өйрәтү; 2. юашландыру, басынкыландыру, тыйнаклandыру; йөгәнләү, авызлыклау; тыю; басу; *укротить шалуна* — шук малайны басынкыландыру; *укротить гнев* — ачуны басу; 3. *перен. книж.* бетерү, бастыру; туктату, сүндерү; *укротить мятеж* — фетнәне бастыру; *укротить пожар* — янгынны сүндерү.

**УКРОТИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. юашлану, басынкылану; кулга өйрәнү, буйсыну; *шалун укротился* — шаян малай басынкыланды; 2. *книж.* басылу, тынычлану; *гнев укротился* — ачу басылды.

**УКРОЩА'ТЬ** *несов.* — к. укротить.

**УКРОЩА'ТЬСЯ** *несов.*— 1. к. укротиться; 2. *страд.* буйсындырылу, кулга өйрәтелү; тынычландырылу.

**УКРУПНЕ'НИЕ** *ср. офиц.* — 1. к. укрупнить; 2. к. укрупниться.

**УКРУПНЁННЫЙ** *офиц.* — эреләнгән(дерелгән, берләштерелгән.

**УКРУПНИ'ТЬ** *сов. офиц.* — эреләндерү, берләштерү.

**УКРУПНИ'ТЬСЯ** *сов. офиц.*— берләшү, эреләнү.

**УКРУПНЯ'ТЬ** *несов. офиц.* — к. укрупнить.

**УКРУПНЯ'ТЬСЯ** *несов. офиц.* — 1. к. укрупниться; 2. *страд.* эреләндерелү, берләштерелү.

**УКРУТИ'ТЬ** *сов.* — 1. *разг.* урап бәйләү, уратып бәйләү; *укрутить воз верёвками* — йөкне баулар белән уратып бәйләү; 2. *старин.* киендерү, киендерү-ясандыру (кәләшне никахка).

**УКРУТИ'ТЬСЯ** *сов. разг.* — урану, урап бәйләү.

**УКРУ'ЧИВАТЬ** *несов. разг. старин.* — к. укрутить.

**УКРУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов. разг.* — к. укрутиться.

**УКРЫВА'ТЕЛЬ** *м.* **УКРЫВА'ТЕЛЬНИЦА** *ж. право, офиц.* — яшереп тотучы, яшереп торучы, яшереп саклаучы (мәсәлән, урланган әйберне).

**УКРЫВА'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *офиц.* — (җинаятьчене, җинаять эзләрен) яшерү, яшереп тоту, яшереп саклау, яшереп тору.

**УКРЫВА'ТЬ** *несов.* — к. укрыть.

**УКРЫВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. укрыться; 2. *страд.* төрелү, ябылу, каплану, бөркәлү; 3. *страд.* яшерелү, яшереп саклану, сыендырылу.

**УКРЫ'ВИСТЫЙ** *спец.* — (буяла торган әйбергә) буяу яхшы төшүчән, яхшы буялучан (буяу турында).

**УКРЫ'ТИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. укрыть 1, 2; 2. *воен.* укрытие (дошман утыннан саклану өчен махсус корылма яки чокыр); *стрелять из укрытий* — укрытиедән торып ату.

**УКРЫ'ТЫЙ** — 1. төрелгән, өсте ябылган (мәс., баланың); 2. сакланган, ышыкланган, яшеренгән, капланган; *укрытый от ненастья* — явымнардан капланган (ышыкланган); 3. *воен.* укрытиедәге, укрытиегә яшерелгән (мәсәлән, гаскәр).

**УКРЫ'ТЬ** *сов.* — 1. (өстенә) ябу, ябындыру, каплау, бөркәү, төрү; *укрыть ребёнка одеялом* — баланың өстенә одеял ябу; 2. яшерү, саклау; яшереп тоту, яшереп саклау; *укрыть раненого партизана* — яралы партизанны яшереп саклау; 3. *устар.* ябу (кәрт уенында).

**УКРЫ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. ябыну, каплану, бөркәнү, төренү; *укрыться одеялом* — одеял ябыну; 2. яшеренү, качу; ышыклану;

*укрыться от дождя* — яңгырдан ышыклану; 3. күренми калу, сизелми калу, читтә калу; *ничто не укрылось от его взгляда* — аның карашыннан берни дә читтә калмады.

**УКРЮ'К** *м. обл.* — 1. очына элмәкле бау тагылган корык (өер атларын тоту өчен); 2. ияр чокыры.

**У'КСУС** *м. мн.* нет — серкә (аш серкәсе).

**У'КСУСНИК** *м.* — 1. *бот.* серкә агачы (Төньяк Америкада үсә торган агач); 2. серкә савыты.

**У'КСУСНИЦА** *ж.* — серкә савыты.

**УКСУСНОКИ'СЛЫЙ** *хим.* — серкә кислотасы ...-ы; серкә кислотасы кушылган.

**У'КСУСНЫЙ** — серкә ...-ы; серкәле; *уксусный вкус* — серкә тәме; *уксусная бутылка* — серкә шешәсе. ◇ **Уксусная эссенция** *торг.* — серкә эссенциясе (серкә кислотасының бик көчле эретмәсе). **Уксусное дерево** *бот.* — к. уксусник 1.

**УКУПИ'ТЬ** *сов. простореч.* — (барысын) сатып алу, сатып алып бетерү.

**УКУ'ПОРИВАТЬ** *несов.* — к. укупорить.

**УКУ'ПОРИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — томалап куелу.

**УКУ'ПОРИТЬ** *сов.* — 1. төрү, төреп кую, бәйләп салып кую; 2. бөке тыгу, бөке тыгып чыгу, бөкеләү; *укупорить бутылки* — шешәләргә бөке тыгып чыгу.

**УКУ'ПОРКА** *ж.* — 1. *только ед.* к. укупорить; 2. *спец.* бөке тыккыч (шешәләрне бөкеләү өчен махсус җайланма); 3. *спец. только ед.* төрү әйберләре (материалы).

**УКУ'ПОРОЧНЫЙ** *спец.* — төрү ...-ы; бөке тыгу ...-ы; *укупорочный материал* — төрү әйберләре; *укупорочная машина* — бөке тыгу машинасы.

**УКУ'ПОРЩИК** *м.*, **УКУ'ПОРЩИЦА** *ж. спец.* — төрүче; бөке тыгучы (эшче).

**УКУ'С** *м.* — 1. к. укусить; 2. *разг.* тешләү ярасы; тешләнгән урын, чагылган урын.

**УКУСИ'ТЬ** *сов.* — 1. тешләү, тешләп алу, тешләп яралау; *собака укусила мне ногу* — аягымны эт тешләде; 2. *простореч.* (*ужалить*) чагу, тешләү; 3. *простореч.* тешләп өзү, тешләп алу; *чёрствой корки не укусить* — каткан икмәкне тешләп алып булмый. ◇ **Какая муха укусила?** *кого (разг. фам.)* — нигә кәефе киткән? нигә авызы салынган? аңа ни булган?

**УКУ'ТАТЬ** *сов.* — төрү, төрендерү; урау; (томалап) ябу.

**УКУ'ТАТЬСЯ** *сов.* — төренү, урану, ябыну, бөркәнү.

**УКУ'ТЫВАТЬ** *несов.* — к. укутать.

**УКУ'ТЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. укутаться; 2. *страд.* төрелү, уралу; томалану.

**УЛА'ВЛИВАТЕЛЬ** *м. спец.* — к. уловитель.

**УЛА'ВЛИВАТЬ** *несов.* — к. уловить.

**УЛА'ВЛИВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. тотылу; 2. *перен.* сизелү, тоелу, аңлашылу.

**УЛА'ДИТЬ** *сов.* — 1. җайлау, рәтләү, көйләү, хәл итү, юлга салу; *уладить дело* — эшне җайлау; 2. *устар.* (*примирить*) килештерү, дуслаштыру, татулаштыру; 3. *обл.* төзәтү, рәтләү, көйләү; *уладить борону* — тырманы төзәтү.

**УЛА'ДИТЬСЯ** *сов.* — 1. җайлану, көйләнү, хәл ителү; рәтләнү, юлга салыну, эзгә керү; *дело уладилось* — эш җайланды; 2. *устар.* (*примириться*) килешү, татулашу, килешеп китү, татулашып китү.

**УЛА'ЖИВАТЬ** *несов.* — к. уладить.

**УЛА'ЖИВАТЬСЯ** *несов.* — 1. к. уладиться; 2. *страд.* җайлаштырылу; килештерелү; татулаштырылу.

**УЛА'МЫВАТЬ** I *несов. разг. фам.* — к. уломать.

**УЛА'МЫВАТЬ** II *несов. обл.* — к. уломить.

**УЛА'МЫВАТЬСЯ** I *несов. страд. разг. фам.* — күндерелү, ышандырылу (үз ягына, фикеренә).

**УЛА'МЫВАТЬСЯ** II *несов. страд. обл.* — сындырылу, сындырып алыну.

**УЛА'Н** *м. дореvол.* — улан (патша Россиясендә җиңел кавалериядә хезмәт итүче гаскәри).

**УЛА'НКА** *ж. дореvол.* — улан мундиры, уланка.

**УЛА'НСКИЙ** *дореvол.* — улан ...-ы; *уланский полк* — улан полкы; *уланская форма* — улан формасы (киеме).

**УЛА'СТИТЬ** *сов. простореч. обл.* — иркәләп күндерү, юмалап күндерү.

**УЛА'ЩИВАТЬ** *несов. простореч. обл.* — к. уластить.

**УЛА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч. обл.* — иркәләп күндерелү, юмалап күндерелү.

**УЛЕЖА'ТЬ** *сов. разг.* — (берникадәр вакыт) ятып тору, ятып түзеп тору.

**УЛЕЖА'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — 1. (берәр урында) ятарга өйрәнеп китү, ятарга күнегеп китү; *улежался на диване и вставать не хочется* — диванда ятарга күнегеп киттем, торасы да килми; 2. к. слежаться.

**УЛЕЗА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. улезть.

**УЛЕ'ЗТЬ** *сов. простореч.* — шуышып китү, үрмәләп китү.

**У'ЛЕЙ** *м.* — умарта.

**УЛЕПЕТНУ'ТЬ** *однокр. разг. фам.* — к. улепётывать.

**УЛЕПЁТЫВАТЬ** *несов. разг. фам.* — элдертү, сыпырту, таю, сызу, шылу, качу, качып китү, укчә күтәрү, табан ялтырату. ◇ **Улепётывать со всех ног** — җан-фәрманга чабып качу.

**УЛЕПИ'ТЬ** *сов. простореч.* — 1. ябыштырып чыгу, ябыштырып бетерү; 2. ябыштырып бетерү, ябыштырып сыйдыру.

**УЛЕПИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — ябыштырылып сыю, ябыштырылып сыеп бетү.

**УЛЕПЛЯ'ТЬ** *несов. простореч.* — к. улепить.

**УЛЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. улепиться; 2. *страд.* ябыштырылу, ябыштырып чыгылу; ябыштырып бетерелү.

**УЛЕСТИ'ТЬ** *сов. простореч.* — юмалап алдау, юмалап күндерү, кызыктырып алдау.

**УЛЁТ** *м. мн.* нет, *обл.* — очу, очып китү (кошлар).

**УЛЕТА'ТЬ** *несов.* — к. улететь.

**УЛЕТЕ'ТЬ** *сов.* — **1.** очу, очып китү; *птицы уже улетели* — кошлар очып китте инде; **2.** *перен. разг. фам.* китеп бару, чабу, йөгерү; *не дослушав, он улетел домой* — тыңлап та бетермичә, ул өенә чапты; **3.** *перен.* бик тиз үтеп китү, узып китү; *время улетело* — вакыт бик тиз үтеп китте.

**УЛЕТУ'ЧИВАТЬ** *несов. спец.* — к. улетучить.

**УЛЕТУ'ЧИВАТЬСЯ** *несов.* — к. улетучиться.

**УЛЕТУ'ЧИТЬ** *сов. спец.* — парга әйләндереп бетерү, (парга әйләндереп) очырып бетерү (тиз очып бетә торган матдәләр турында).

**УЛЕТУ'ЧИТЬСЯ** *сов.* — **1.** *спец.* *(испариться)* очу, очып бету, парга әйләнеп бетү; кибеп бетү; **2.** *перен. разг.* сызу, шылу, таю; җилләр исү, юкка чыгу, юк булу; *он улетучился из дому* — ул өйдән чыгып сызды.

**УЛЕ'ЧЬСЯ** *сов.* — **1.** яту, йокларга яту, ял итәргә яту; *все в доме улеглись* — өйдәгеләр барысы да йокларга яттылар; **2.** *(уместиться)* сыю, сыеп бетү (тар җиргә ятканда яки әйбер тутырганда); **3.** *перен.* к. уложиться 5; **4.** басылу; куну, утыру; *пыль улеглась* — тузан басылды; **5.** *перен.* *(успокоиться, утихнуть)* тыну, басылу; тынычлану; туктау; *ветер улёгся* — җил басылды.

**УЛЕЩА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. улестить.

**УЛЕЩА'ТЬСЯ** *несов. простореч. страд.* — юмалап күндерелү, юмалап алдану, кызыктырылу.

**УЛЕ'ЩИВАТЬ** *несов. простореч.* — юмалау, кызыктыру.

**УЛЕ'ЩИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — к. улещаться.

**УЛИВА'ТЬ** *несов. простореч.* — к. улить.

**УЛИЗНУ'ТЬ** *сов. разг фам.* — качу, качып китү; таю, шылу.

**УЛИ'КА** *ж.* — җинаять билгесе, гаеп, дәлил; *оправдать за отсутствием улик* — гаебе булмау сәбәпле аклау.

**УЛИ'ТА** *ж. обл.* — к. улитка.

**УЛИ'ТКА** *ж.* — **1.** *зоол.* әкәм-төкәм, тәкәмөкә (бик әкрен хәрәкәт итүче моллюск); **2.** *анат.* әкәм-төкәм, бормача (колак эчендә тавыш ишетү үзәге урнашкан бер әгъза); **3.** *тех.* улитка, бормача (машина детале).

**УЛИ'ТКИ** *только мн. зоол.* — әкәм-төкәмнәр, әкәм-төкәмнәр классы.

**УЛИТКООБРА'ЗНЫЙ** — әкәм-төкәмсыман.

**УЛИ'ТЬ** *сов. простореч.* — **1.** түгеп бетерү; *вся скатерть улита вином* — бөтен эскәтергә кызыл аракы түгеп бетергәннәр; **2.** (беразын) түгү, түгеп кимету; *улить воды из бочки* — мичкәдән бераз суны түгү.

**У'ЛИЦА** *ж.* — **1.** урам; *центральная улица* — үзәк урам; **2.** *(место вне помещения)* тыш, урам; *на улице жара* — тышта эссе; **3.** *перен. устар. презрит.* урам халкы, мещаннар, обывательләр; **4.** *перен.* урам (җәмгыять, мәктәп, гаиләнең культура йогынтысыннан читтә булган мохит); *влияние улицы на детей* — балаларга урамның тәэсире; **5.** *перен. только ед. устар.* фахишәлек, урам тормышы; *порвать с улицей* — фахишәлекне ташлау. ◇ **Выбросить на улицу** *перен.* — к. выбросить. **Зелёная улица** — яшел урам (юл, семафор ачык мәгънәсендә). **На улице оказаться** — урамда калу (эшсез яки акчасыз калу). **С улицы** *разг.* — урамнан (очраклы кеше, билгесез кеше турында). **Про то знает вся улица** — моны бөтен урам белә.

**УЛИЦЕЗРЕ'ТЬ** *сов. книж. ирон.* — к. лицезреть.

**УЛИЧА'ТЬ** *несов.* — к. уличить.

**УЛИЧА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — гаебе ачылу, фаш ителү, (җинаять өстендә) тотылу.

**УЛИЧИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — гаебен ачучы, фаш итүче, йөзен ачучы.

**УЛИЧИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. редко* — гаебен ача торган, фаш итә торган, гаепли торган (җинаятьне исбат итә торган).

**УЛИЧИ'ТЬ** *сов.* — гаебен ачу, йөзен ачу, фаш итү; (җинаять өстендә) тоту; гаепле икәнен күрсәтү.

**У'ЛИЧКА** *ж.* — кечкенә урам, тыкрык.

**У'ЛИЧНЫЙ** — урам ...-ы; урамдагы; *уличный сторож* — урам каравылчысы; *уличный шум* — урамдагы шау-шу. ◇ **Уличный мальчишка** *устар. разг. бран.* — урам малае (көннең күп вакытын урамда үткәрә торган тәртипсез малай). **Уличные нравы** *презрит. устар.* — урамча гадәтләр, урам гадәтләре. **Уличная девка** *устар. вульг.* — фахишә, урам кызы.

**УЛО'В** *м.* — тотым, тотылган балык, тотылган балык күләме.

**УЛОВИ'МЫЙ** *книж.* — тотып алына торган; ишетеп алына торган; аңлап алына торган.

**УЛО'ВИСТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *обл. спец.* — балыкны күп тоту мөмкинлеге.

**УЛО'ВИСТЫЙ** *обл. спец.* — балык күп эләгә торган, балык шәп тотыла торган, балык шәп эләгә торган; *уловистое место* — балык шәп тотыла торган урын; *уловистая сеть* — балык шәп эләгә торган ятьмә.

**УЛОВИ'ТЕЛЬ** *м. спец.* — тоткыч, тотып алгыч, тоткыч аппарат.

**УЛОВИ'ТЬ** *сов.* — **1.** тоту, тотып алу; *уловить радиоволну* — радио дулкынын тоту; **2.** *перен.* сизеп алу; аңлап алу, күреп алу, тотып алу, ишетеп алу; отып алу; *уловить насмешку в чьих-н. словах* — берәүнең сүзендә мыскыллау сизеп алу; **3.** *перен. разг.* файдалану, файдаланып калу, тотып алу; *уловить удобный случай* — уңай очрактан файдалану.

**УЛОВИ'ТЬСЯ** *сов. безл. разг.* — тотылу, эләгү, кабу.

**УЛО'ВКА** *ж.* — хәйлә, мәкер, сылтау, әмәл; *никакие уловки не помогли* — берниндн сылтау да файда итмәде.

**УЛОВЛЯ'ТЬ** *несов. устар.* — **1.** к. уловить; **2.** *ритор., теперь ирон.* аулау, җә-

леп итү; *уловлять сердца* — күнелләрне аулау.

**УЛОВЧИ'ТЬСЯ** *сов. простореч.* — к. изловчиться.

***УЛОЖЕ'НИЕ** *ср. истор.* — законнар җыентыгы, законнар мәҗмугасы.

**УЛОЖИ'ТЬ** *сов.* — **1.** яткыру, яткызу; *уложить в кровать* — караватка яткыру; **2.** йокларга яткыру; *мать уложила детей* — ана балаларын йокларга яткырды; **3.** тутыру, урнаштыру, салу, тутырып кую, салып кую; *уложить вещи в чемодан* — әйберләрне чемоданга салып кую; **4.** *перен.* (билгеле бер чиккә) сыйдыру; *уложить статью в один лист* — мәкаләне бер биткә сыйдыру; **5.** җәю, түшәү; *уложить двор камнем* — ишек алдына таш җәю; **6.** (билгеле бер тәртиптә) салу; өю, өеп кую; *уложить дрова в поленницу* — утынны әрдәнәләп өю; **7.** *перен. разг. (убить)* үтерү, бәреп үтерү; **8.** *старин. (постановить, определить)* карар кылу, билгеләп кую. ◇ **Уложить в голове** *разг.* — башка сыйдыру (аңлау, төшенү). **Уложить в гроб** *разг.* — үтерү, кабергә кертү, гүргә кертү, үлемгә китереп җиткерү.

**УЛОЖИ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** *разг.* юлга җыену, юлга әзерләнү, юлга чыгар алдыннан әйберләрне төреп кую; *спешно уложиться* — ашыгыч рәвештә юлга җыену; **2.** сыю, сыеп бетү; *все вещи не уложатся в чемодан* — чемоданга бар әйбер дә сыеп бетмәс; **3.** *перен. разг.* сыю, кереп бетү; *уложиться в смету* — сметага сыю; **4.** җитү, җитеп бару; *уложиться в свой заработок* — алган эш хакың җитеп бару; **5.** *перен.* (башка) сыю, аңга җитү; *новое известие не могло уложиться в его голове* — яңа хәбәр аның башына сыя алмады; **6.** *перен.* туры килү, сыю; ярашып бетү, сыешып бетү; *уложиться в обычные рамки* — гадәттәге чикләргә туры килү; *это не может уложиться в обычные представления* — бу гадәти төшенчәләргә сыешып бетми.

**УЛОМА'ТЬ** *сов. разг. фам.* — (үгетләп) күндерү, сүз тыңлату; ышандыру, бөгү.

**УЛОМИ'ТЬ** *сов. обл.* — сындыру, сындырып алу, каерып алу.

**У'ЛОЧКА** *ж. разг. фам.* — кечкенә урам, тыкрык.

**УЛУ'С** *м.* — олыс (**1.** борынгы күчмә халыкларда — вакытлы тору урыны, табор; **2.** кайбер халыкларда — авыл; **3.** элек кайбер халыкларда — билгеле бер ыру һәм аңа караган җир; **4.** Якутия АССРда — район).

**УЛУ'СНЫЙ** — олыс ...-ы; *улусный староста* — олыс старостасы.

**УЛУЧА'ТЬ** *несов.* — к. улучить.

**УЛУЧА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — (вакыт) табылу, туры китерелү.

**УЛУЧИ'ТЬ** *сов.* — (вакыт) табу, туры китерү, форсат табу.

**УЛУЧША'ТЬ** *несов.* — к. улучшить.

**УЛУЧША'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** к. улучшиться; **2.** *страд.* яхшыртылу, яхшыга таба үзгәртелү.

**УЛУЧШЕ'НИЕ** *ср.* — **1.** *только ед.* к. улучшить; **2.** *только ед.* к. улучшиться; **3.** үзгәреш, яхшыртылыш; камилләштерү; *в машину введён ряд новых улучшений* — машинага күп кенә яңа камилләштерүләр кертелгән (машина камилләштерелгән).

**УЛУ'ЧШИТЬ** *сов.* — яхшырту, төзәтү, сыйфатын күтәрү.

**УЛУ'ЧШИТЬСЯ** *сов.* — яхшыру, әйбәтләнү, яхшыга таба үзгәрү, төзәлү.

**УЛЫ'БА** *м.* и *ж. разг. фам., нар.-поэт.* — көләч, көлемсәр.

**УЛЫБА'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** елмаю, елмаеп көлү; елмаеп карау, көлемсерәү; **2.** *перен.* (тормыш) яхшы бару, уңышлы бару, шәп бару, җырлап бару; уңай килеп тору; *жизнь ему улыбалась* — аның тормышы бик яхшы бара иде; *ему фортуна всегда улыбается* — язмыш аңа һәрвакыт уңай килеп тора; **3.** *перен.* алда тору, алда көтү (киләчәктә буласы күңелле бер нәрсә турында); *впереди ему улыбался солидный заработок* (М. Горький) — алда аны шактый зур эш хакы көтә иде; **4.** *перен. разг.* ошау; күңелгә яту; *эта работа мне не улыбается* — бу эш миңа ошамый.

**УЛЫ'БКА** *ж.* — елмаю, елмаеп көлү, көлемсерәү.

**УЛЫБНУ'ТЬСЯ** *сов.* — **1.** к. улыбаться; **2.** елмаеп кую; көлемсерәп кую; **3.** *перен. разг. фам. (пропасть)* югалу, җилләр исү, юкка чыгу, очу; *улыбнулись часики* — сәгатьтән җилләр искән.

**УЛЫ'БЧИВЫЙ** *простореч.* — елмаючан, көлемсәр.

**УЛЬИ'ШКО** *м. разг. пренебр.* — умарта кисәге, начар умарта.

**УЛЬТИМАТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ультимативлылык, ультиматив булу, катгыйлык.

**УЛЬТИМАТИ'ВНЫЙ** *книж.* — ультиматив, ультиматив рәвештәге, ультиматум рәвешендәге; катгый, кискен.

**УЛЬТИМАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — ультиматизм (Россия социал-демократик хәрәкәтендә 1908 елда отзовизмның бер төре буларак мәйданга килгән оппортунистик агым).

**УЛЬТИМАТИ'СТ** *м. полит.* — ультиматизм тарафдары.

**УЛЬТИМА'ТНЫЙ** *устар.* — к. ультимативный.

**УЛЬТИМА'ТУМ** *м.* — ультиматум (**1.** *полит.* халыкара мөнәсәбәтләрдә — бер илнең икенче бер илгә каршы килгән хәлдә билгеле бер тәэсир итү чараларын куллану белән, хәтта сугыш белән янап, катгый таләп куюы; *предъявить ультиматум* — ультиматум белдерү; **2.** *книж.* гомумән — янаулы таләп, куркыту юлы белән таләп итү, катгый таләп).

**УЛЬТРАЗВУ'К** *м. физ.* — ультратавыш, ишетелми торган тавыш (тирбәнү ешлыгы секундка 15–20 мең герцтан арткан һәм колак белән ишетеп булмый торган тавыш).

**УЛЬТРАЗВУКОВО'Й** *физ.* — ультратавышлы.

**УЛЬТРАКРА'СНЫЙ** *физ.* — к. инфракрасный.

**УЛЬТРАКОРО'ТКИЙ** *физ.* — ультракыска (дулкыннар).

**УЛЬТРАМАРИ'Н** *м. мн.* нет — ультрамарин (ачык зәңгәр төстәге минераль буяу).

**УЛЬТРАМАРИ'НОВЫЙ** — ультрамарин төсле, ачык зәңгәр.

**УЛЬТРАФИОЛЕ'ТОВЫЙ** *физ.*: **ультрафиолетовые лучи** — ультрафиолет нурлар, ультрамиләүшә нурлар (спектрда фиолет нурлардан соң килә торган, күзгә күренмәслек кыска нурлар).

**УЛЮЛЮ'** *межд. охот.* — улюлю, өсс-өсс (җәнлек куганда этне өстерү сүзе).

**УЛЮЛЮ'КАТЬ** *несов.* — 1. *охот.* улюлю дип кычкыру, өсс дип кычкыру, өстерү; 2. *перен. разг. неодобр. (глумиться)* мыскыллау, мәсхәрә итү, хурлап көлү.

**УЛЯГНУ'ТЬ** *сов. простореч.* — тибү, тибеп җибәрү, тибеп кую (ат турында).

**УМ** *м.* — 1. *только ед.* акыл; *здравый ум* — сәламәт акыл; *человек с умом* — акыллы кеше (башлы кеше); 2. *(сознание)* аң, акыл; 3. *чаще мн.* җәмәгатьчелек фикере; *брожение в умах* — җәмәгатьчелек фикеренең уянуы; 4. *перен.* акыл иясе, фикер иясе; *лучшие умы человечества* — кешелекнең иң зур акыл ияләре. ◇ **Без ума быть** *(от кого-чего) разг.* — акылдан язу, шашу (бик нык соклану). **Без ума** *(делать что-н.)* — белмичә, төшенмичә (эшләү). **Браться за ум** — к. браться. **В своём уме** *разг.* — акылы сәламәт, үз акылында. **Не в своём уме** — акылыннан шашкан, акылында түгел. **В уме ли ты?** *разг.* — акылыңдамы син? акылың бармы? **В уме** *(делать что-н.)* — күңелдән, хәтердән (эшләү, исәпләү, һ. б.); *два пишу, один в уме* — икене язам, берсе күңелдә (арифметик исәпләүләрдә). **Выжить из ума** — к. выжить. **Выходить из ума** — истән чыгу, онытылу. **Задним умом крепок** — аның акылы төштән соң. **И в уме не было, и в уме нет** *разг.* — күңелендә дә булмады, исендә дә юк, уйлаганы да юк. **Из ума вон** *разг. фам.* — истән чыккан, хәтердән чыккан, онытып җибәргән. **Из ума нейдёт** или **не идти с ума** — к. идти. **Короткий ум** *разг.* — акылы кыска. **На уме** или **в уме** *(у кого) разг.* — бар белгәне ...; уенда ... гына. **На ум наставить** *(кого) разг.* — акыл бирү, өйрәтү, нишләргә кирәклеген өйрәтү. **Не нашего ума дело** *разг. фам.* — безнең баш җитәрлек эш түгел, без аңларлык эш түгел. **От большого ума** *разг. ирон.* — акыллы башланып, ахмакланып. **Повредиться в уме** *простореч.* — акылы зәгыйфьләнү, акылына зыян килү. **Повреждённый в уме** *разг.* — акылы зәгыйфьләнгән, акылдан язган. **Прийти на ум** или **в ум** *(кому) разг.* — 1. башына килү; теләү; 2. башына килү, фикер төшү. **Раскинуть умом** — к. раскинуть. **Свести с ума** — 1) акылдан яздыру, акылдан шаштыру; 2) *перен.* хәйран калдыру, акылдан шаштыру, әсир итү. **Себе на уме** — к. себя. **Сойти** (спятить, свихнуть, своротить, спрыгнуть) **с ума** — тилерү, акылдан язу, акылдан шашу. **С умом (делать** *что-н.)* — акыл белән, баш белән, уйлап (эшләү). **Сходить с ума** *разг.* — акылдан шашу (бик мавыгу, соклану мәгънәсендә). **Терять ум** *разг.* — башны югалту, акылны югалту, баш-күз әйләнү. **Считать в уме** — күңелдән исәпләү. **Ум-разум** *разг. нар.-поэт.* — акыл. **Уму-разуму учить** *разг.* — акылга өйрәтү, акыл бирү, үгет-нәсихәт бирү. **Ума не приложить** *разг.* — акыл җитмәү, төшенмәү, аңлый алмау. **Ума палата** — к. палата. **Ум за разум заходит** — к. разум. **Уму непостижимо** — к. непостижимый. **Уму помрачение** — к. помрачение.

**УМА'ЗАТЬ** *сов.* — 1. *обл.* сылау, сылап чыгу; *умазать плетень глиной* — читәнне балчык белән сылау; 2. *разг. (запачкать)* пычрату, буяп бетерү.

**УМА'ЗАТЬСЯ** *сов. разг.* — пычранып бетү, буялып бетү.

**УМА'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. умазать.

**УМА'ЗЫВАТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг.* к. умазаться; 2. *страд.* пычратылу; сылану.

**УМА'ИВАТЬ** *простореч. несов.* — к. умаять.

**УМА'ИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — 1. к. умаяться; 2. *страд.* арытылу, хәлдән тайдырылу.

**УМАКНУ'ТЬ** *сов. разг.* — к. обмакнуть.

**УМАЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — к. умалить, умалиться.

**УМА'ЛИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. умолять 1.

**УМАЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.* — к. уменьшительный.

**УМАЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. *устар.* киметү, азайту; *умалить доходы* — килерне киметү; 2. *перен.* төшерү, түбәнәйтү, кечерәйтү; *умалить авторитет* — авторитетын төшерү.

**УМАЛИ'ТЬСЯ** *сов. книж.* — 1. *устар. (уменьшиться)* кимү, азаю, кечерәю; 2. *перен.* төшү, түбәнәю; кечерәю; *достоинство его умалилось* — дәрәҗәсе төште.

**УМАЛИШЁННЫЙ** — акылдан шашкан, акылдан язган; җүләр, тиле.

**УМА'ЛЧИВАТЬ** *несов.* — 1. к. умолчать; 2. дәшми тору, әйтми тору.

**УМА'ЛЧИВАТЬСЯ** *несов. безл.* — искә алынмау, әйтелмәү, сөйләнмәү, телгә алынмау, сүз булмау.

**УМАЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. умалить.

**УМАЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — 1. к. умалиться; 2. *страд.* киметелү, азайтылу, кечерәйтелү; 3. *страд.* (дәрәҗәсе, әһәмияте) төшерелү, түбәнәйтелү, кечерәйтелү.

**УМА'НИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. уманить.

**УМА'НИВАТЬСЯ** *несов. страд. простореч.* — кызыктырылу, кызыктырып алып кителү.

**УМАНИ'ТЬ** *сов. простореч.* — кызыктырып алып китү, алдап алып китү, ияртеп алып китү.

**УМА'СЛИВАТЬ** *несов.* — к. умаслить.

**УМА'СЛИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. умаслиться.

**УМА'СЛИТЬ** *сов.* — 1. *простореч.* (бик нык) майлау, май ягу, май сөртү, майга батыру; *умаслить блины* — беленне майлау;

2. *перен. разг. фам.* юмалап күндерү, майлау, майлап күндерү.

**УМА'СЛИТЬСЯ** *сов. простореч.* — майлау, май сөртенү; май сөртү (мәсәлән, чәчкә).

**УМАСТИ'ТЬ** *сов. книж. устар.* — хуш исле май сөртү, сөртү.

**УМАСТИ'ТЬСЯ** *сов. книж. устар.* — хуш исле май сөртенү.

**УМА'ТЫВАТЬ** *несов. простореч.* — к. умотать.

**УМА'ТЫВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. умотаться.

**УМАЩА'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. умастить.

**УМАЩА'ТЬСЯ** *несов. книж. устар.* — 1. к. умаститься; 2. *страд.* хуш исле май сөртелү.

**УМА'ЩИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. умостить.

**УМА'ЩИВАТЬСЯ** *несов. простореч.* — к. умоститься.

**УМА'ЯТЬ** *сов. простореч.* — арыту, ардыру, арытып бетерү, алҗыту, йончыту, йончытып бетерү, хәлдән тайдыру; җәфалау, җәфалап бетерү, интектереп бетерү.

**УМА'ЯТЬСЯ** *сов. простореч.* — ару, алҗу, йончу, хәлдән таю, арып бетү, йончып бетү, җәфаланып бетү.

**У'МБРА** *ж. мн.* нет — умбра (көрән төстәге минераль буяу).

**УМЕ'ДЛИТЬ** *сов. разг.* — әкренәйтү, әкренәйтә төшү, (бераз) әкренәйтеп кую.

**УМЕ'ДЛИТЬСЯ** *сов. разг.* — (бераз) әкренәю, әкренәя төшү.

**УМЕДЛЯ'ТЬ** *несов. разг.* — к. умедлить.

**УМЕДЛЯ'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. умедлиться; 2. *страд.* әкренәйтелү, әкренәйтеп куелу.

**УМЕ'ЛЕЦ** *м.*— оста, оста кул, маһир, белгеч.

**УМЕ'ЛО** *нареч.* — оста итеп, белеп.

**УМЕ'ЛЫЙ** — оста; оста куллы, маһир.

**УМЕЛЬЧА'ТЬ** *несов. разг.* — к. умельчить.

**УМЕЛЬЧА'ТЬСЯ** *несов. разг.* — 1. к. умельчиться; 2. *страд.* вагайтылу, кечерәйтелү.

**УМЕЛЬЧИ'ТЬ** *сов. разг.* — кечерәйтү, ваклау, вагайту.

**УМЕЛЬЧИ'ТЬСЯ** *сов.* — кечерәю, вагаю, ваклану.

**УМЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — белү, белем; булдыра алу, сәләт; осталык.

**УМЕНЬША'ЕМОЕ** *ср. в знач. сущ. мат.* — кимүче (сан).

**УМЕНЬША'ЕМЫЙ** — кечерәйтелмәле, кечерәйтелә торган.

**УМЕНЬША'ТЬ** *несов.* — к. уменьшить.

**УМЕНЬША'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. уменьшиться; 2. *страд.* кечерәйтелү, азайтылу, киметелү.

**УМЕНЬШЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. уменьшить, уменьшиться; 2. кимү күләме, кимү зурлыгы, кимү.

**УМЕНЬШИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *лингв.*: **категория уменьшительности** — кечерәйтү категориясе.

**УМЕНЬШИ'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. кечерәйтә торган, кечерәйтеп күрсәтә торган, кечерәйткеч; *уменьшительное стекло* — кечерәйтеп күрсәтә торган пыяла; 2. *лингв.* кечерәйтелгән; киметүле, кечерәйтү ...-ы; *уменьшительный суффикс* — кечерәйтү кушымчасы; *уменьшительные существительные* — кечерәйтелгән исемнәр; 3. кыскартылган, кыскартып әйтелгән (кеше исемнәре, мәсәлән, Габдулла — Апуш, Виталий — Витя һ. б. ш).

**УМЕ'НЬШИТЬ** *сов.* — кечерәйтү, азайту, киметү; *уменьшить объём* — күләмен кечерәйтү; *уменьшить дозу* — дозасын азайту.

**УМЕ'НЬШИ'ТЬСЯ** *сов.* — кечерәю, азаю, киму.

**УМЕ'РЕННО** *нареч.* — чамалап, чама белән, уртача.

**УМЕ'РЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — уртачалык, уртача булу; сабыр (тыйнак, гади) булу.

**УМЕ'РЕННЫЙ** I — 1. урта, уртача; *умеренный климат* — уртача климат; 2. уртача, урта дәрәҗәдәге, чамалы, чикле, чикләнгән; *умеренные желания* — чикләнгән теләкләр; 3. сабыр, тыйнак, гади (күпкә омтылмый, күпне теләми торган); *умеренный характер* — сабыр холык; *умеренная жизнь* — гади тормыш; 4. *полит.* урталык ...-ы; *умеренная политика* — урталык политикасы (урта юл тоту политикасы).

**УМЕ'РЕННЫЙ** II *простореч.* — ким үлчәнгән, киметеп үлчәнгән.

**УМЕРЕ'ТЬ** *сов.* — 1. үлү, үлеп китү, вафат булу; *умереть от раны* — ярадан үлү; 2. *книж. (за кого-что и без доп.)* корбан булу, җан бирү, башын салу, һәлак булу; *умереть за родину* — туган ил өчен корбан булу; 3. *перен.* үлү, сүнү, бетү, юкка чыгу; *дело наших отцов не умрёт* — атабабаларыбызның эше үлмәс. ◇ **Умереть со смеху** — к. умереть. **Тут со скуки умрёшь** — монда эч пошудан үләрсең (гаҗиз булырсың).

**УМЕ'РИВАТЬ** *несов. простореч.* — к. умéрить II.

**УМЕ'РИТЬ** I *сов.* — 1. чикләү, чик кую; чикли төшү; киметү, киметә төшү; *умерить требования* — таләпләрне киметә төшү; 2. тыю, басу, йөгәнләү; *умерить гнев* — ачуны басу.

**УМЕ'РИТЬ** II *сов. простореч.* — ким үлчәү, ким итеп үлчәү (ялгышып яки алдау нияте белән).

**УМЕ'РИТЬСЯ** *сов.* — (бераз) чикләнү, кимү, кими төшү; басылу, басыла төшү; *требования умерились* — таләпләр кимеде; *гнев умерился* — ачу басылды.

**УМЕРТВИ'ТЬ** *сов. книж.* — 1. үтерү; 2. *спец.* үлеләндерү (сизмәс хәлгә китерү); *умертвить нерв больного зуба* — сызлый торган тешнең нервын үлеләндерү; 3. *перен.* үтерү, бетерү, юк иту, басу; *умертвить плоть* — дәртне басу.

**УМЕ'РШИЙ** — үлгән, вафат булган, мәрхүм.

**УМЕРЩВЛЯ'ТЬ** *несов. книж.* — к. умертвить.

**УМЕРЩВЛЯ'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.*—

1. үтерелү, һәлак ителү; 2. үлеләндерелү (сизмәслек хәлгә китерелү).

**УМЕРЯ'ТЬ** *несов.* — к. умерить I.

**УМЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. умериться; 2. *страд.* (бераз) чикләнелү, киметелү; басылу (мәсәлән, ачу).

**УМЕСИ'ТЬ** *сов. обл.* — к. вымесить.

**УМЕСТИ'** *сов. разг.* — себереп кую, себереп чыгару, себереп ташлау.

**УМЕСТИ'ТЬ** *сов.* — сыйдыру, сыйдырып бетерү; урнаштыру, урнаштырып бетерү.

**УМЕСТИ'ТЬСЯ** *сов.* — сыю, сыеп бетү; урнашу, урнашып бетү.

**УМЕ'СТНО** *нареч.* — урынлы, нигезле.

**УМЕ'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — урынлылык, нигезлелек; урынлы булу.

**УМЕ'СТНЫЙ** — урынлы, нигезле.

**УМЕТА'ТЬ** I *несов. разг.* — к. умести.

**УМЕТА'ТЬ** II *сов. обл.* — 1. кую, салу; *уметать стог* — кибән кую; 2. (тирәли һәм өстенә) түшәү, каплау; *уметать шалаш землёю* — шалашны балчык белән каплау.

**УМЕТА'ТЬСЯ** *несов. страд. разг.* — себерелү, себереп куелу, себерелеп чыгарылу.

**УМЁТЫВАТЬ** *несов. обл.* — к. уметать II.

**УМЁТЫВАТЬСЯ** *несов. обл. страд.* — 1. куелу, салыну; 2. каплану, түшәлү.

**УМЕ'ТЬ** *несов.* — белү, эшли алу, эшли белү, булдыру, кулыннан килү; *уметь плавать* — йөзә белү.

**УМЕ'ШАННЫЙ** *обл.* — болгатылган.

**УМЕША'ТЬ** *сов. обл.* — болгату, бутау; тугылау.

**УМЕ'ШЕННЫЙ** *обл.* — изелгән, басылган.

**УМЕ'ШИВАТЬ** I *несов. обл.* — к. умесить.

**УМЕ'ШИВАТЬ** II *несов. обл.* — к. умешать.

**УМЕ'ШИВАТЬСЯ** I *несов. страд. обл.* — изелү, басылу.

**УМЕ'ШИВАТЬСЯ** II *несов. страд. обл.* — болгатылу, тугылану.

**УМЕЩА'ТЬ** *несов.* — к. уместить.

**УМЕЩА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. к. уместиться; 2. *страд.* урнаштырылу, сыйдырылу.

**УМЕ'ЮЧИ** *нареч. разг.* — белеп, оста, осталык белән, иплән.

**УМИЛЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — күңел йомшару, күңел нечкәрү, тәэсирләнү; *прийти в умиление* — күңел йомшарып китү.

**УМИЛЁННЫЙ** — 1. *устар.* шәфкать уятылган; күңеле йомшартылган; күңеле нечкәртелгән; 2. күңеле нечкәргән, күңеле йомшарган, тәэсирләнгән; *умилённый взор* — тәэсирләнгән караш.

**УМИЛИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — сөйкемлелек, ягымлылык, сокландыргыч булу.

**УМИЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** — сокландыргыч, ягымлы, сөйкемле; күңелне нечкәртә торган, күңелне йомшарта торган; *умилительный ребёнок* — сөйкемле бала.

**УМИЛИ'ТЬ** *сов.* — 1. *устар.* (*склонить к жалости*) кызгандыру, җәлләтү, шәфкать уяту, кызгану тойгысы уяту; 2. (*растрогать*) күңелне йомшарту, күңелне нечкәртү, тәэсирләндерү, эретеп җибәрү.

**УМИЛИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. *устар.* кызгану тойгысы уяну, кызганып кую, җәлләп җибәрү; шәфкать килү; *умилились сердца злодеев* — явызларның күңелләренә шәфкать килде; 2. күңел нечкәрү, күңел йомшарып китү; тәэсирләнеп китү; *мать умилилась видом ребёнка* — баласының йөзен күргәч, ананың күңеле нечкәреп китте.

**УМИЛОСЕ'РДИТЬ** *сов. книж. устар.* — к. умилостивить.

**УМИЛОСЕ'РДИТЬСЯ** *сов. книж. устар.* — к. умилостивиться.

**УМИ'ЛОСТИВИТЬ** *сов. книж. устар.* — шәфкатьлеләндерү, мәрхәмәтлеләндерү, шәфкать уяту, күңелен йомшарту.

**УМИ'ЛОСТИВИТЬСЯ** *сов. книж. устар.* — күңеле йомшару, мәрхәмәтләнү, мәрхәмәте килү, шәфкатьләнү.

**УМИЛОСТИВЛЯ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — к. умилостивить.

**УПРУ'ЖИТЬ** *несов. спец.*— сыгылмалы итү, эластик итү.

**УПРЫ'ГАТЬ** *сов. разг.*— сикерә-сикерә китү, сикерә-сикерә китеп бару.

**УПРЫ'ГАТЬСЯ** *сов. разг.*—1. (*устать прыгая*) сикерә-сикерә ару, сикереп арып бетү; 2. *перен. шутл. фам.* күп сикеренә алмау, дәрте сүнү, дәрманы бетү; *взялся за дело горячо, но скоро упрыгался* — эшкә бик кызып тотынган иде дә, ләкин дәрманы тиз бетте.

**УПРЫ'ГИВАТЬ** *несов. разг.*— к. упрыгать.

**УПРЫ'ГНУТЬ** *однокр. разг.*— сикереп китү, сикерү.

**УПРЯГА'ТЬ** *несов. обл.*— к. упрячь.

**УПРЯ'ЖКА** *ж.*—1. җигем, бергә җигелгән атлар; *шестерик в упряжке* — җигемдә алты ат; 2. *горн.* упряжка (бер сменада эшләүче тау эшчеләре төркеме); 3. *обл.* (җигелгән) арба, чана; *обоз в десять упряжек* — ун чанадан торган олау;4. *только ед.* к. упряжь; 5. *обл.* җигү (атларны ашатмыйча, алмаштырмыйча үткән ара); *мы в город ездили в две упряжки* — без ике җигүдә шәһәргә барып җитә идек.

**УПРЯЖНО'Й** — 1. дирбия ...-ы; 2. җигем ...-ы; җигә торган, җигү ...-ы; җигүлек; *упряжные лошади* — җигү атлары.

**У'ПРЯЖЬ** *ж. мн.* нет — 1. дирбия, сбруй (җигү кирәк-яраклары); *конская упряжь* — ат сбруе (йөгән, ияр, камыт һ. б.); 2. *ж.-д.* тимер юл вагоннарын бер-берсенә тоташтыру җайланмасы.

**УПРЯ'МЕЦ** *м. разг.*— кире кеше, тискәре кеше, үҗәт, киребеткән, үзсүзле (кеше).

**УПРЯ'МИТЬСЯ** *несов.*— киреләнү, тискәреләнү, үзсүзләнү, кәҗәләнү, үҗәтләнү, карышу.

**УПРЯ'МИЦА** *ж. разг.*— к. упрямец.

**УПРЯ'МО** *нареч.*— үзсүзләнеп, киреләнеп, тискәреләнеп; кирелек белән... .

**УПРЯ'МСТВО** *ср. мн.* нет — кирелек, тискәрелек, үзсүзлелек, үҗәтлек, карышу.

**УПРЯ'МСТВОВАТЬ** *несов. книж.*—1. (үз сүзендә) нык тору, үзенекен итү, үзенекен яклау; 2. к. упрямиться.

**УПРЯ'МЫЙ** — кире, үзсүзле, үҗәт, тискәре; киребеткән; *упрямый ребёнок* — кире бала. ◇ **Факты — упрямая вещь** — хакыйкать таш яра (ягъни фактларга каршы торып булмый).

**УПРЯ'ТАТЬ** *сов. разг.*— 1. яшерү, яшереп кую; җыеп кую; *упрятать вещи* — әйберләрне яшереп кую; 2. *перен.* олактыру, ябып кую, утырту (мәсәлән, төрмәгә).

**УПРЯ'ТАТЬСЯ** *сов. разг.*— яшеренү, качу, кереп посу.

**УПРЯ'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. упрятать.

**УПРЯ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. к. упрятаться; 2. *страд.* яшерелү, яшереп куелу, җыеп куелу.

**УПРЯ'ЧЬ** *сов. обл.*— к. запрячь.

**УПУСКА'ТЬ** *несов.*— к. упустить.

**УПУСКА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— кулдан ычкындырылу; әрәм ителү; (истән) чыгарылу.

**УПУСТИ'ТЬ** *сов.*—1. кулдан ычкындыру, ычкындырып җибәрү, төшерү, төшереп җибәрү; *упустить конец верёвки* — бауның очын кулдан ычкындыру; 2. *перен.* ычкындыру, югалту, әрәм җибәрү. ◇ **Упустить из виду** — к. вид.

**УПУ'ТАТЬ** *сов. разг.*— урау, чорнау, чорнап алу, урап алу.

**УПУ'ТЫВАТЬ** *несов. разг.*— к. упутать.

**УПУ'ТЫВАТЬСЯ** *несов. разг. страд.*— уралу, чорналу, урап алыну, чорнап алыну.

**УПУЩЕ'НИЕ** *ср.*— кимчелек, житешсезлек, күреп җиткермәү, игътибарсызлык, гамьсезлек; ялгышлык.

**УПЫ'РЬ** *м.*—1. убыр; 2. зур яркапат.

**УПЯТЕРИ'ТЬ** *сов.*— биш тапкыр арттыру, бишләтә арттыру.

**УПЯТЕРИ'ТЬСЯ** *сов.*— бишләтә арту, биш тапкыр арту.

**УПЯТЕРЯ'ТЬ** *несов.*— к. упятерить.

**УПЯТЕРЯ'ТЬСЯ** *несов.*— к. упятериться.

**УРА'** *междом.*—1. ура; 2. ура тавышы, ура кычкыру. ◇ **На ура — 1.** ура кычкырып (атакага бару); 2. *перен. разг. ирон.* хәзерләнмичә, очраклы уңышка ният итеп, алдын-артын уйламыйча.

**УРАВНЕ'НИЕ** *ср.*—1. к. уравнять, уравняться; 2. *мат.* тигезләмә; *квадратное уравнение* — квадрат тигезләмә.

**УРА'ВНИВАТЬ** I *несов.*— к. уравнять.

**УРА'ВНИВАТЬ** II *несов.*— к. уровнять.

**УРА'ВНИВАТЬСЯ** I *несов.*— 1. к. уравняться; 2. *страд.* тигезләштерелү, тигезләндерелү, тиңләштерелү, бертигез ителү.

**УРА'ВНИВАТЬСЯ** II *несов.*—1. к. уровняться; 2. *страд.* такырайтылу, тигезләп чыгылу.

**УРАВНИ'ЛОВЕЦ** *м. неодобр.*— уравниловкачы, уравниловка яклы, тигезләүчелек яклы.

**УРАВНИ'ЛОВКА** *ж. мн.* нет, *неодобр.*— тигезләүчелек, тигезләштерүчелек, уравниловка.

**УРАВНИ'ЛОВСКИЙ** *неодобр.*— тигезләүчелек ...-ы; уравниловкага нигезләнгән; *уравниловские тенденции* — тигезләүчелек тенденцияләре.

**УРАВНИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — тигезләүчелек, тигезләүгә омтылучанлык.

**УРАВНИ'ТЕЛЬНЫЙ** —1. *спец.* тигезләүче, тигезли торган, тигезләү...-ы; тигез; *уравнительные пошлины* — тигезләү пошлиналары; 2. *книж.* тигезләүчелек...-ы; *„уравнительный социализм“ Дюринга* — Дюрингның „тигезләүчелек социализмы“.

**УРАВНОВЕ'СИТЬ** *сов.*—1. тигезләү, тигезлеккә китерү (үлчәүдә); 2. *перен.* тигезләштерү, бертигез итү; *уравновесить силы* — көчләрне тигезләштерү.

**УРАВНОВЕ'СИТЬСЯ** *сов.*—1. тигезләнү, тигезлеккә килү; *чашки весов уравновесились* — үлчәү тәлинкәләре тигезләнде; 2. тигезләшү, бертигез булу; *силы уравновесились* — көчләр тигезләште.

**УРАВНОВЕ'ШЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — сабыр холыклылык, сабырлык.

**УРАВНОВЕ'ШЕННЫЙ**—1. (*о весах и т. п.*) тигезләнгән, тигезләндерелгән, тигезләтелгән; 2. (*о человеке*) сабыр, сабыр холыклы, басынкы.

**УРАВНОВЕ'ШИВАТЬ** *несов.*— к. уравновесить.

**УРАВНОВЕ'ШИВАТЬСЯ** *несов.*— 1. к. уравновеситься; 2. *страд.* тигезләтелү, тигезләштерелү.

**УРАВНЯ'ТЬ** *сов.*— тигезләү, бертигез итү; тиңләү, тиңләштерү, тигезләштерү.

**УРАВНЯ'ТЬСЯ** *сов.*— тигезләнү, тигезләшү, бертигез булу, тиңләшү, бәрабәр булу.

**УРАГА'Н** *м.*—1. өермә, давыл; 2. *перен. книж.* ташкын; *ураган страстей* — дәртләр ташкыны. ◇ **Промчался ураганом** — җил-давылдай үтеп китте.

**УРАГА'ННЫЙ** —1. давыл ...-ы, өермә...-ы; *ураганные явления* — өермә күренешләре; 2. *перен.* өермәдәй көчле, давылдай көчле; *открыть ураганный огонь* — өермәдәй көчле ут ачу.

**УРАЗУМЕВА'ТЬ** *несов. книж.*— к. уразуметь.

**УРАЗУМЕВА'ТЬСЯ** *несов. книж. страд.*— аңлану.

**УРАЗУМЕ'ТЬ** *сов. книж.*— аңлау, төшенү, аңлап җиткерү, аңлап алу, төшенеп алу.

**УРА'ЛЕЦ** *м.*—1. Урал кешесе, Уралда яшәүче; 2. Урал казагы, Җаек казагы.

**УРА'ЛЬСКИЙ** — урал...-ы; *уральские казаки* — Урал казаклары (Урал елгасы буенда яшәүче казаклар, борынгыча Җаек казаклары); *уральские самоцветы* — Урал асылташлары.

**УРА'Н** *м. мн.* нет, *хим.*— уран (радиоактивлык үзлекләре булган ак металл — химик элемент).

**УРА'НОВЫЙ** *хим.*— уран ...-ы; *урановая руда* — уран рудасы.

**УРА'-ПАТРИО'Т** *м. презрит.*— ура-патриот, ялган патриот, ялган ватанчы.

**УРА'-ПАТРИОТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *презрит.*— ура-патриотлык, ялган ватанчылык, ялган патриотизм.

**УРБАНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *социол.*— урбанизация, шәһәрләштерү (илнең бөтен экономик һәм культура тормышын эре шәһәр үзәкләренә туплау — капиталистик җәмгыятькә хас күренеш).

**УРБАНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— урбанизм, шәһәрчелек (1. зур капиталистик шәһәрдәге югары катлауларның төшенке культурасы; 2. матди һәм мәдәни тормышны эре шәһәр үзәкләрендә туплауны яклаучы буржуаз агым; 3. *лит. искус.* әдәбият һәм сәнгатьтә шәһәр стихиясе мотивларының өстенлек итүе).

**УРБАНИ'СТ** *м. книж.*— урбанист, урбанизм тарафдары.

**УРБАНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж. искус.* — урбанизм ...-ы; урбанистик; урбанистлык ...-ы; урбанизмга хас булган; *урбанистическая поэзия* — урбанистик поэзия.

**УРВА'ТЬ** *сов. разг.*— 1. умырып алу, йолкып алу, умыру, йолку; **2.** *перен. фам.* алу, чумырып алу; 3. *перен. разг. фам.* табу, табып файдалану; *урвать время* — вакыт табу.

**УРВА'ТЬСЯ** *сов. разг. фам.*— бушанып чыгу, ерынып чыгу, ычкыну; *кое-как ур-*

*ваться из дому* — ничек кирәк алай өйдән ерынып чыгу.

**УРЕГУЛИ'РОВАТЬ** *сов.* — к. регулировать.

**УРЕГУЛИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* — тәртипкә салыну, көйләнү, җайлану, рәткә салыну.

**УРЕ'З** *м. мн.* нет, *спец.* — к. урезать. ◇ **Урез воды** *тех.* — су өсте, су өсте сызыгы (ике як яр буенда су күтәрелеше линиясе); *ширина канала по урезу воды — 140 метров, по дну — 60 метров* — каналның киңлеге су өсте буенча — 140 метр, төбе буенча — 60 метр.

**УРЕ'ЗАННЫЙ** — 1. киселгән, кисеп алынган, кисеп кыскартылган; 2. кыскартылган, киметелгән; *урезанные расходы* — кыскартылган расходлар; 3. ярым-йорты, өтек; *урезанная демократия* — өтек демократия (капитал илләрендә).

**УРЕ'ЗАТЬ** *сов.* — 1. *простореч.* кисеп кыскарту; кисеп киметү; *урезать полы одежды* — киемнең чабуларын кисеп кыскарту; 2. *перен.* киметү, кыскарту, кисү; *урезать расходы* — чыгымнарны киметү; *урезать штаты* — штатларны кыскарту. ◇**Урезать муху** *простореч. фам.* — аракы эчү (салу, кагу).

**УРЕЗА'ТЬ** *несов. разг.* — к. урéзать.

**УРЕЗА'ТЬСЯ** *несов. разг. страд.* — к. урезываться.

**УРЕ'ЗКА** *ж. разг.* — к. урéзать.

**УРЕ'ЗНИК** *м. спец.* — итекче пычагы.

**УРЕЗО'НИВАТЬ** *несов. разг.* — к. урезонить.

**УРЕЗО'НИТЬ** *сов. разг.* — (дәлилләр белән) ышандыру, күндерү.

**УРЕ'ЗЫВАТЬ** *несов.* — к. урéзать.

**УРЕ'ЗЫВАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. кисеп кыскартылу; 2. киметелү, кыскартылу.

**УРЕМА'** *ж. обл.* — әрәмә.

**УРЕМИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — уремия, сидек канлану, бәвел канлану авыруы.

**УРЕ'ТРА** *ж. анат.* — уретра, сидек юлы, бәвел юлы.

**УРЕТРИ'Т** *м. мед.* — уретрит, сидек юлы ялкынсыну.

**УРЕТРОСКО'П** *м. мед.* — уретроскоп (сидек юлын тикшерү көзгесе).

**УРИ'ЛЬНИК** *м. устар.* — бәвел чүлмәге, төнге чүлмәк.

**УРИ'НА** *ж. мн.* нет, *физиол. мед.* — бәвел, сидек.

**УРМА'Н** *м. обл.* — урман.

**У'РНА** *ж.* — урна (1. яндырылган мәетнең көлен саклау өчен ваза рәвешендәге савыт; 2. *поэт.* савыт, ваза; 3. сайлау бюллетеньнәре сала торган ящик; 4. җәмәгать урыннарындагы яки урамдагы чүп савыты).

**УРОБИЛИ'Н** *м. мн.* нет, *физиол.* — уробилин (сидектә була торган буяу матдәсе, үт пигменты).

**У'РОВЕНЬ** *м.* — 1. биеклек, биеклек дәрәҗәсе; тигезлек; *уровень воды при наводнении сильно повышается* — ташу вакытында елгада суның биеклеге бик нык күтәрелә; *уровень моря* — диңгез тигезлеге; 2. *перен.* дәрәҗә; *уровень знаний* — белем дәрәҗәсе; 3. *спец.* тигезләгеч, ватерпас; ◇ **В уровень** — 1) тигез, бер тигезлектә *вода в ведре в уровень с краями* — су чиләкнең чите белән тигез; 2) *перен.* бергә, бер адым белән; *идти в уровень с веком* — заман белән бергә атлау.

**УРОВНЯ'ТЬ** *сов.* — тигезләү, тигезләп чыгу, такырайту.

**УРОВНЯ'ТЬСЯ** *сов.* — такыраю; тигезләнү.

**УРО'Д I** *м.* — 1. гарип, имгәк; 2. *разг.* ямьсез кеше, иләмсез кеше; 3. имгәк. ◇ **Нравственный урод** — әхлаксыз кеше. **В семье не без урода** — аттан ала да туа, кола да туа.

**УРО'Д II** *м. обл.* — уңыш (иген уңышы).

**УРО'ДЕЦ** *м. разг. фам.* — 1. гарип, имгәк; 2. ямьсез кеше, иләмсез кеше.

**УРО'ДИНА** *м.* и *ж. разг., фам. пренебр., бран.* — к. урод I.

**УРОДИ'ТЬ** *сов.* — 1. *спец., обл.* уңыш бирү; җимеш бирү; 2. *простореч.* тудыру.

**УРОДИ'ТЬСЯ** *сов.* — 1. уңу, булу; 2. *разг.* охшау, охшап туу; *уродился в отца* — атасына охшап туган.

**УРО'ДИХА** *ж. простореч. устар.* — к. урод I.

**УРО'ДИЩЕ** *м.* и *ж. разг., фам. пренебр. бран.* — к. уродина.

**УРО'ДЛИВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. гариплек; 2. ямьсезлек, шыксызлык; 3. *перен.* бозыклык, мәгънәсезлек, әшәкелек.

**УРО'ДЛИВЫЙ** — 1. гарип; *уродливая рука* — гарип кул; 2. ямьсез, шыксыз, котсыз, иләмсез, килбәтсез; *уродливая внешность* — ямьсез кыяфәт; 3. *перен.* бозык; әшәке; мәгънәсез, бозылган; чатак; *уродливое воспитание* — бозык тәрбия; *уродливое выражение* — чатак тәгъбир.

**УРО'ДОВАТЬ** *несов.* — 1. гарипләү, гариплэндерү; имгәтү, гарип калдыру; *тяжёлые ранения уродуют людей* — авыр яралар кешене гариплэндерә; 2. ямьсезләү, шыксызлау; бозу; *уродовать себя нелепой причёской* — килешми торган причёска белән үзеңне ямьсезләү; 3. вату, бозу, ерту; *уродовать игрушки* — уенчыкларны вату; *уродовать книгу* — китапны ерту; 4. *перен.* бозу; *уродовать чужую мысль* — кеше фикерен бозу.

**УРО'ДОВАТЬСЯ** *несов.* — 1. гарипләнү, ямьсезләнү; үз-үзеңне гариплэндерү, кыяфәтеңне бозу; 2. *страд.* гариплэндерелү, бозылу, имгәтелү, гарип калдырылу.

**УРО'ДСКИЙ** — гарип ...., гарип ...-ы; гарип кешенеке кебек, табигый булмаган, бозык.

**УРО'ДСТВО** *ср.* — 1. гариплек, физик кимчелек; *уродство часто является следствием болезни* — гариплек еш кына авырудан кала; 2. *только ед. (безобразная внешность)* ямьсезлек, килбәтсезлек, шыксызлык; 3. *перен.* бозыклык, мәгънәсезлек, әшәкелек; *нравственное уродство* — әхлаксый бозыклык.

**УРОЖА'Й** *м.* — 1. уңыш (иген һәм җиләк-җимеш уңышы); *собрать весь урожай* — бөтен уңышны җыеп алу; 2. уңыш, мул уңыш; *несколько лет были урожаи* — бер-

ничә ел рәттән уңыш булды; 3. *перен. разг. шутл.* муллык, күплек, бик күп булу; *теперь урожай на новые книги* — хәзер яңа китаплар бик күп.

**УРОЖА'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. *книж.* уңыш, уңышлылык, мул уңышлылык; 2. *с.-х.* уңдырыш, уңдыручанлык (туфракның, җирнең, үсемлекнең уңыш бирү дәрәҗәсе); *повышение урожайности* — уңдырышны күтәрү.

**УРОЖА'ЙНЫЙ** — 1. *спец.* уңыш ...-ы; уңыш турындагы; *урожайные сведения* — уңыш турындагы мәгълүматлар; 2. иген уңган; иген уңа торган; *урожайный год* — иген уңган ел; 3. мул уңыш алган; күп уңыш ала торган, күп уңыш бирә торган; *урожайный колхоз* — мул уңыш алган колхоз; *урожайные сорта винограда* — виноградның күп уңыш бирә торган сортлары.

**УРОЖДА'ТЬ** *несов. редко* — к. уродить.

**УРОЖДА'ТЬСЯ** *несов. редко* — к. уродиться.

**УРОЖДЁННАЯ** *офиц.* — кыз фамилиясе..., кыз вакытындагы фамилиясе... (кияүгә чыгып фамилиясе үзгәргән хатын турында әйтелә).

**УРОЖЕ'НЕЦ** *м.*, **УРОЖЕ'НКА** *ж.* — туган, тумышы белән...-лы; ... да туган; *он уроженец Казани* — ул Казанда туган.

**УРО'К** *м.* — 1. *устар. спец.* (билгеле бер срокка бирелгән) эш; *задать урок плотникам* — балта осталарына эш кушу; 2. *устар., спец.* (берәр эшкә) бирелгән вакыт, мөддәт; *отсидеть свой урок* — үзеңә бирелгән вакытны үткәрү; 3. дәрес, сабак (билгеле бер фәнгә багышланган уку сәгате); *сегодня пять уроков* — бүген биш дәрес; 4. дәрес, өйгә эш; 5. *перен.* үгет, үгет-нәсихәт, сабак, акыл өйрәтү; *урок ваш выслушала я* (Пушкин) — тыңладым мин сезнең үгетне; 6. *разг.* җәза, сабак; *дать легкий урок* — җиңелчә җәза бирү; 7. гыйбрәт; сабак; *уроки истории* — тарих сабаклары; *уроки прошлого* — үткәннең сабаклары. ◇ **Брать уроки** — хосусый рәвештә уку, хосусый рәвештә дәрес алу; *брать уроки музыки* — хосусый рәвештә музыка дәресләре алу. **Давать уроки** — 1) дәрес бирү, укыту; 2) хосусый рәвештә дәресләр бирү, хосусый рәвештә укыту. **Жить на уроке** (у кого, где) *устар.* — (берәүдә) хосусый укытучы булып яшәү.

**УРО'ЛОГ** *м. спец.* — уролог (урология белгече, урология врачы).

**УРОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — урология ...-ы; *урологический кабинет* — урология кабинеты (больницада, амбулаториядә).

**УРОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — урология (медицинаның җенес-сидек әгъзалары авырулары турындагы бер бүлеге).

**УРО'Н** *м. мн.* нет, *книж.* — югалту, зыян, зарар; *нанести урон врагу* — дошманны югалтуга дучар итү.

**УРОНИ'ТЬ** *сов.* — 1. (кулдан) төшерү, ычкындыру, төшереп җибәрү; төшереп калдыру; төшереп югалту; *уронить книгу* — китапны кулдан төшереп җибәрү; 2. салу; *уронил голову на подушку* (Тургенев) — башын мендәргә салды; 3. тамызу; *уронить горячую слезу* — кайнар яшь тамызу; 4. *перен.* дәрәҗәсен төшерү, абруен төшерү; *себя не уронил* (Гоголь) — үзенең дәрәҗәсен төшермәде; 5. *разг.* сүз дәшү, сүз әйтү; *урони словечко* — бер сүз әйтсәнә.

**У'РОСИТЬ** *обл.* — чыгымчылау, киреләнү.

**У'РОСЛИВЫЙ** *обл.* — чыгымчы, кире.

**УРОТРОПИ'Н** *м. мн.* нет, *хим. апт.* — уротропин (сидек юлларын чистарту өчен кулланыла торган кристаллсыман төссез порошок).

**УРО'ЧИЩЕ** *ср.* — 1. табигый ызан, табигый чик (мәсәлән, елга, урман, тау, чокыр һ. б.); 2. үзенә бер табигый урын, табигый бүлемтек (мәсәлән, ачык кыр уртасындагы урман, сазлык яки күл).

**УРО'ЧНЫЙ** — 1. *устар.* билгеләнгән; сүз куешкан, вәгъдәләшкән, сөйләшенгән, сөйләшкән; *урочный час настал* — билгеләнгән сәгать җитте; 2. *спец.* шарт буенча билгеләнгән, килешү буенча билгеләнгән, килешү буенча сөйләшенгән, тиешле; *урочное время* — (берәр эшне үтәү өчен) билгеләнгән вакыт; *урочная цена* — килешү буенча билгеләнгән бәя, тиешле бәя. ◇ **Урочное положение** *спец.* — кагыйдәләр һәм нормалар җыентыгы (төзү эшендә).

**УРУБА'ТЬ** *несов. простореч. спец.* — к. урубить.

**УРУБА'ТЬСЯ** *несов. страд. простореч. спец.* — чабып алып кыскартылу, кисеп алып кыскартылу.

**УРУБИ'ТЬ** *сов. простореч. спец.* — чабып алып кыскарту, кисеп алып кыскарту (озын әйбернең бер өлешен).

**УРЧА'ТЬ** *несов.* — 1. шарлап агу, гөрләп агу; *вода урчит* — су шарлап ага; 2. *(о собаке)* ырылдау; 3. богырдау, чурлау; кычкыру; *в желудке урчит* — эч богырдый; 4. гөрелдәү.

**УРЫВА'ТЬ** *несов. разг.* — к. урвать.

**УРЫВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *разг. фам.* к. урваться; 2. *страд.* умырып алыну.

**УРЫ'ВКАМИ** *нареч. разг.* — өзек-өзек, урык-сурык, ара-тирә; вакыт-вакыт; эштән бушаган araларда; *видеться урывками* — ара-тирә күрешкәләү; *работать урывками* — өзек-өзек эшләү.

**УРЫ'ЛЬНИК** *м.* — к. урильник.

**УРЮ'К** *м. мн.* нет — өрек, өрек җимеше (киптергән абрикос җимеше).

**УРЯ'Д** *м. старин.* — 1. тәртип, куелыш; 2. дәрәҗә, чин, урын (эштә).

**УРЯДИ'ТЬ** *сов. старин., обл.* — 1. хәзерләү, әзерләү, җыю, хәстәрләү; *урядить в дорогу* — юлга җыю; 2. киендерү, киендерү-ясандыру; 3. тәртипкә китерү, тәртипкә салу.

**УРЯДИ'ТЬСЯ** *сов. старин. обл.* — җыену, әзерләнү; *урядиться в дорогу* — юлга җыену.

**УРЯ'ДНИК** *м. доревол.* — урядник (1. патша армиясенең казачи гаскәрләрендәге унтер-офицер; 2. өяз полициясендәге түбән чин).

**УРЯ'ДНИЧИЙ** *доревол.* — урядник ...-ы; урядниклык ...-ы; *урядничьи нашивки* — урядниклык тасмалары.

да, халык фикеренчә, өстен чыгарга тиеш булган як).

**ФАВОРИТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — фаворитизм (иҗтимагый тормышның берәр өлкәсендә фаворитлар хөкем сөрүе).

**ФАВОРИ'ТКА** *ж. книж. устар.* — фаворитка (югары дәрәҗәле кешенең яратканы, аның химаясеннән файдаланучысы).

**ФАГО'Т** *м. муз.* — фагот (тынлы музыка коралы).

**ФАГОТИ'СТ** *м. муз.* — фаготта уйнаучы, фаготчы.

**ФАГОЦИ'Т** *м. биол.* — фагоцит (каты матдәләрне һәм бактерияләрне йота торган органик күзәнәк).

**ФАГОЦИТО'З** *м. мн.* нет, *биол.* — фагоцитоз (фагоцитларның каты матдәләрне һәм бактерияләрне йотуы).

**ФА'ЗА** *ж.* — фаза (1. *книж.* чор, дәвер, тарихи үсешнең билгеле бер дәвере; *социализм — первая фаза коммунизма* — социализм — коммунизмның беренче фазасы; 2. *астр.* берәр планетаның, мәсәлән, айның, яктыртылган өлешенең җиргә карата төрле торышта булуына карап күренеше үзгәрү процессындагы аерым момент яки чор; 3. *физ.* берәр матдәнең формасы яки халәте үзгәрүендәге аерым момент яки чор; *твёрдая фаза* — катылык фазасы; *жидкая фаза* — сыеклык фазасы; 4. *физ.* берәр периодик күренешнең теге я бу моменты яки стадиясе; *фазы колебания маятника* — маятник тирбәнешләренең фазалары (тирбәнеш вакытында аның төрле торышлары); 5. *физ. тех.* күп фазалы генератор обмоткаларының аерым группасы).

**ФАЗА'Н** *м.* — фазан (тавыкчалар семьялыгыннан бер кош).

**ФАЗА'НИЙ** — фазан...-ы; *фазаньи крылья* — фазан канатлары.

**ФАЗАНИ'НА** *ж. мн.* нет — фазан ите.

**ФА'ЗИС** *м. книж.* — фазис (берәр процессның яки күренешнең үсешендәге аерым дәвер).

**ФАЗО'МЕТР** *м. физ. тех.* — фазометр (алмаш ток чылбырында ток белән киеренкелек арасындагы үзгәрешнең фазаларын үлчи торган прибор).

**ФАЙ** *м. мн.* нет — фай (ефәк тукыманың бер төре).

**ФАЙДЕШИ'Н** *м. мн.* нет — файдешин (ефәк тукыманың яхшы сорты).

**ФАЙДЕШИ'НОВЫЙ** — файдешин..., файдешиннан тегелгән; *файдешиновая блузка* — файдешиннан тегелгән блузка, файдешин блузка.

**ФА'КЕЛ** *м.* — факел (1. бер башына сумалалы чүбек урап ут кабызылган таяк; 2. *астр.* кояш өстендәге аеруча ачык яктырып торган урын).

**ФА'КЕЛЬНЫЙ** — факел...-ы; *факельный свет* — факел яктысы. ◇ **Факельное шествие** — факеллар тотып урамда йөрү.

**ФА'КЕЛЬЦУГ** *м. устар.* — факеллар белән бару, факеллар тотып урамда йөрү.

**ФА'КЕЛЬЩИК** *м.* — 1. *устар.* факел тотып баручы; 2. *перен. презрит.* сугыш уты кабызучы, ут төртүче.

**ФАКИ'Р** *м.* — 1. дәрвиш; 2. фокус күрсәтүче.

**ФАКСИ'МИЛЕ** *ср. нескл.* — 1. факсимиле (кульязманың, имзаның, документның фотографиясе яки басма ярдәмендә нәкъ үзе итеп төшерелгән күчермәсе); 2. *в знач. неизм. прил.* или *нареч.* нәкъ үзе итеп басылган, төшерелгән, үзгәртелмичә басылган, төшерелгән; *рукопись издана факсимиле* — кульязма үзгәртелмичә басылган.

**ФАКТ** *м.* — факт, булган эш, чын вакыйга. ◇ **Факт, что...** — дөрестән дә, чыннан да; *факт, что мы победим в соревновании* — чыннан да без ярышта җиңеп чыгачакбыз. **Факт тот, что...** *разг.* — эш шунда,...; *факт тот, что времени осталось мало* — эш шунда, вакыт аз калды.

**ФАКТИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — фактта, асылда, чынында, чынлыкта; *в капиталистических странах миллионы трудящихся фактически лишены избирательных прав* — капиталистик илләрдә миллионнарча хезмәт ияләре сайлау хокукыннан асылда мәхрүм ителгәннәр.

**ФАКТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. фактик, фактка нигезләнгән; *фактический материал* — фактик материал; *фактические данные* — фактик мәгълүматлар; 2. фактта..., чынында..., фактик; *фактическое начало работы* — фактта (чынында) эшнең башланып китүе. ◇ **Факти́ческий брак** — язылмыйча өйләнешү.

**ФАКТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — фактларга туры килү.

**ФАКТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — фактларга туры килә торган; *материал недостаточно фактичен* — материал фактларга бик үк туры килми.

**ФА'КТОР** *м.* — фактор (1. берәр процессның, күренешнең этәргеч көче, сәбәбе, шарты; *постоянно действующие факторы* — даими рәвештә тәэсир итә торган факторлар; 2. *устар.* комиссионер, сәүдә эшләрендә арадашлык итүче; 3. *тип. устар.* типографиянең техник мөдире; 4. *мат.* тапкырланучы саннарның һәрберсе).

**ФАКТО'РИЯ** *ж.* — фактория (1. колониаль илләрдә Европа купецлары тарафыннан оештырылган сәүдә пунктлары; 2. СССРда — ерактагы промысел районнарында аучыларның товарларын сатып алу һәм аларны промысел кораллары, материаллары, азык-төлек, өй кирәк-яраклары белән тәэмин итәр өчен дәүләт тарафыннан оештырылган пунктлар исеме).

**ФАКТО'РСКИЙ** *устар.* — 1. арадаш...-ы; *факторская услуга* — арадаш ярдәме (сәүдә эшендә); 2. факторлык...-ы; *факторская должность* — факторлык вазифасы (типографиядә).

**ФАКТО'РСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.* — 1. арадашлык вазифасы, арадашлык профессиясе; 2. факторлык (типографиянең техник мөдире вазифасы).

**ФА'КТОРСТВОВАТЬ** *несов. устар.* — арадашлык итү (сәүдә эшләрендә).

**ФА'КТОРША** *ж. разг. устар.*— к. фактор 2.

**ФАКТО'ТУМ** *м. устар.*— фактотум (берәүнең хезмәтендә булып аның барлык эшләрен, йомышларын башкаручы кеше; берәүнең „уң кулы", ышанычлы кешесе).

**ФАКТУ'РА** *ж.*— фактура (1. *только ед.* поэзиядә, музыкада, скульптурада художество техникасының үзенчәлеге; 2. *торг.* җибәрелгән товарның хакын, санын, исемнәрен күрсәтеп, товар алучыга язып җибәрелә торган кәгазь).

**ФАКТУРИ'СТ** *м. торг.*— фактура язучы (сәүдә эшендә).

**ФАКТУ'РНЫЙ** *м. спец.*— фактуралар...-ы; *фактурная книга* — фактуралар кенәгәсе (фактуралар языла торган кенәгә).

**ФАКУЛЬТАТИ'ВНЫЙ** *книж.*— факультатив, ихтыяри, мәҗбүри булмаган, үз карамагына тапшырылган (күбрәк — төрле дәресләр турында).

**ФАКУЛЬТЕ'Т** *м.*— факультет (югары уку йортының билгеле бер фәннәр тармагы өйрәнелә торган бүлеге).

**ФАКУЛЬТЕ'ТСКИЙ** — факультет...-ы; *факультетский совет* — факультет советы.

**ФАЛ** *м. мор.*— фал (корабльләрдә җилкәннәрне, сигнал флагларын һ. б. күтәрү өчен хезмәт итә торган бау).

**ФАЛАЛЕ'Й** *м. простореч. презрит.*— ачык авыз, беркатлы кеше.

**ФАЛА'НГА** *ж.*—1. фаланга (а. *истор.* борынгы грекларда коралланган җәяүле гаскәрнең тыгыз сафка тезелгән строе; б. *перен.* саф, гомумән әйберләрнең яки кешеләрнең тигез итеп тезелгән сафы; в. *истор.* фурьеристларның утопик социализм тәгълиматында — община, коммуна); 2. *анат.* бармак сөяге; 3. *зоол.* бөе (үрмәкүчсыманнар классыннан агулы бөҗәк.)

**ФАЛАНСТЕ'Р** *м. истор. социол.*— фаланстер (фурьеристларның утопик социализм тәгълиматында коммуна тормышының үзәге булган махсус типтагы бина).

**ФАЛБАЛА'** *ж. мн.* нет, *собир.*— бөрмә (хатын-кызлар күлмәгенең итәгендә, зур пәрдәләрдә һ. б.).

**ФА'ЛДА** *ж.*— чабу (фрак, сюртук, мундир чабуы).

**ФА'ЛЕЦ** *м. спец. простореч.*— к. фальц.

**ФА'ЛИНЬ** *м. мор.*— аркан (көймәне пристаньга яки корабльгә бәйләп куя торган аркан).

**ФАЛРЕ'ПЫ** *мн. мор.*— фалреп (суднога трап буйлап менгәндә һәм төшкәндә тотына торган бау).

**ФАЛЬБАЛА'** *м. мн.* нет, *устар.*— к. фалбала.

**ФАЛЬКОНЕ'Т** *м. истор. воен.*— фальконет (кечкенә калибрлы борынгы туп).

**ФАЛЬСИФИКА'Т** *м. спец.*— фальсификат (алдап ясалган продукт, ялган товар).

**ФАЛЬСИФИКА'ТОР** *м. книж.*— фальсификатор (ялган эш белән шөгыльләнүче кеше, начар нәрсәне яхшы итеп бозып күрсәтүче, фактларны бозып күрсәтүче).

**ФАЛЬСИФИКА'ТОРСКИЙ** — фальсификатор (лар)...-ы; фальсификаторларча; *фальсификаторские приемы* — фальсификатор алымнары.

**ФАЛЬСИФИКА'ЦИЯ** *ж. книж.*— 1. фальсификация (а. ялган документ, кулъязма һ. б. ясау; б. алдап эшләү, алдау максаты белән начар нәрсәне яхшы итеп күрсәтү, бозып күрсәтү; в. *перен.* чын, дөрес, яхшы нәрсәне алама, дөрес булмаган, чын булмаган нәрсә белән алмаштыру); 2. ялган, ясалма нәрсә; *это не настоящий кофе, а фальсификация* — бу чын кофе түгел, ә ясалма кофе.

**ФАЛЬСИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— фальсификацияләү, начар нәрсәне яхшы итеп күрсәтү, алдап эшләү, бозып күрсәтү.

**ФАЛЬСИФИЦИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— фальсификацияләнү, начар нәрсә яхшы итеп күрсәтелү, бозып күрсәтелү.

**ФАЛЬСТА'РТ** *м. спорт.*— фальстарт (ялгыш башланган старт).

**ФАЛЬЦ** *м. спец.*— 1. фальц (ике калайның бөгеп ялганган урынындагы) җөй, бөгеш; 2. ырмау, такта ырмавы; 3. *тип.* бөкләнгән урын (басма кәгазь табагының бөкләнү урыны).

**ФАЛЬЦЕ'БЕЛЬ** *м. стол.*— фальцебель (ырмау ясый торган струк).

**ФАЛЬЦЕВА'ЛЬНЫЙ** *спец.*— фальцевать итә торган; *фальцевальный цех* — фальцевать итә торган цех.

**ФАЛЬЦЕВА'ТЬ** *несов. спец.*— фальцевать итү (басма кәгазь битләрен, мәсәлән, басылган китап битләрен билгеле бер тәртиптә бөкләп кую).

**ФАЛЬЦЕВА'ТЬСЯ** *несов. спец. страд.*— фальцевать ителү.

**ФАЛЬЦЕ'Т** *м.*— фальцет (1. ирләрдә хатын-кызлар тавышына охшаган нечкә тавыш; 2. шундый тавыш чыгару ысулы, шундый тавыш белән җырлау).

**ФАЛЬЦО'ВКА** *ж. мн.* нет. *спец.*—к. фальцевать.

**ФАЛЬЦО'ВОЧНЫЙ** —фальцевать итү...-ы, фальцевать итә торган; *фальцовочная машина* — фальцевать итә торган машина.

**ФАЛЬЦО'ВЩИК** *м.*, **ФАЛЬЦО'ВЩИЦА** *ж. спец.*— фальцевать итүче (типографиядә басылган китап һ. б. битләрен бөкләүче эшче).

**ФАЛЬШБО'РТ** *м. мор.*—фальшборт (судно бортының өске палубадан чыгып торган урыны).

**ФАЛЬШИ'ВИТЬ** *несов.*—1. *разг.* икейөзләнү, хәйләләү; 2. көйне бозып җырлау, көйне бозып уйнау; *певец фальшивит* — җырчы көйне бозып җырлый.

**ФАЛЬШИ'ВКА** *ж. разг. презрит.*— ялган документ.

**ФАЛЬШИВОМОНЕ'ТЧИК** *м. ритор. презрит.*— ялган акча ясаучы, ялган акча сугучы.

**ФАЛЬШИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ялгышлык (җырда, уенда); 2. икейөзлелек; 3. ясалма булу, ясалмалылык.

**ФАЛЬШИ'ВЫЙ** — 1. ялган, ясалма; *фаль-*

*шивый паспорт* — ялган паспорт; 2. *муз.* ялгыш, хата; *фальшивая нота* — ялгыш нота; 3. эчкерле, монафыйк, икейөзле; *фальшивый человек* — монафыйк кеше. ◇ **Попасть в фальшивое положение** — уңайсыз хәлдә калу, уңайсыз хәлгә төшү. **Фальшивый монетчик** *простореч.* — к. фальшивомонетчик.

**ФАЛЬШИ'ТЬ** *несов. устар.* — к. фальшивить.

**ФАЛЬШКИ'ЛЬ** *м. мор.* — фальшкиль (комга яки ташка килеп утырганда ватылудан саклау өчен корабльдә киль астына беркетеп куелган агач яки металл борыс).

**ФАЛЬШЬ** *ж. мн.* нет — 1. эчкерлелек, икейөзлелек, монафыйклык; 2. *(обман)* хәрәмләшү, алдашу, алдау; 3. *муз.* ялгышлык (музыка уйнаганда яки җырлаганда); 4. *(искусственность)* ясалмалык.

**ФАМИ'ЛИЯ** *ж.* — 1. фамилия; *переменить фамилию* — фамилияне алмаштыру; 2. ыруг, нәсел; *Пушкин принадлежал к старинной дворянской фамилии* — Пушкин борынгы дворян нәселеннән иде; 3. *разг. устар.* семья, гаилә.

**ФАМИ'ЛЬНЫЙ** — 1. нәсел...-ы, семья...-ы; *фамильный архив Пушкиных* — Пушкиннарның нәсел (семья) архивы; 2. нәселдән килгән; *фамильное сходство* — нәселдән килгән охшашлык; 3. ата-бабадан калган, мирас булып калган; *фамильное серебро* — ата-бабадан калган көмеш әйберләр.

**ФАМИЛЬЯ'РНИЧАТЬ** *несов. разг.* — үзен артык иркен тоту, кешене санга сукмыйча мөгамәлә итү, артык үзсенү, артык игътибарсыз мөгамәлә итү.

**ФАМИЛЬЯ'РНОСТЬ** *ж.* — 1. *только ед.* үзеңне артык иркен тоту, тартынмау, тәкәллефсезлек; 2. *разг.* игътибарсыз кыланыш.

**ФАМИЛЬЯ'РНЫЙ** — артык иркен, тартынусыз, тәкәллефсез; *фамильярный тон* — тәкәллефсез тон.

**ФАМИЛЬЯ'РСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.* — к. фамильярность 1.

**ФА'МУЛУС** *м. спец.* — фамулус (чит ил университетларында профессорның йомышларын үтәүче ассистент яки студент).

**ФАНАБЕ'РИЯ** *ж. разг. неодобр.* — урынсыз һавалылык, тәкәбберлек, эрелек, минминлек.

**ФАНАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — фанатизм (үз фикеренә, идеясенә бик нык ябышып ятучылык, башка кешенең фикеренә түзмәүчелек күрсәтү).

**ФАНА'ТИК** *м.* — фанатик (1. фанатизмга бирелгән кеше; 2. *перен.* берәр эшкә яки идеягә бик нык бирелгән кеше; *фанатик искусства* — сәнгать фанатигы).

**ФАНАТИ'ЧЕСКИЙ** — фанатикларча...; *фанатическая вера* — фанатикларча ышану.

**ФАНАТИ'ЧКА** *ж.* — фанатик хатын-кыз.

**ФАНАТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — фанатиклык.

**ФАНАТИ'ЧНЫЙ** — к. фанатический.

**ФАНДА'НГО** *ср. нескл.* — фанданго (испан халык биюенең исеме).

**ФАНЕ'РА** *ж.* — фанер (1. кыйммәтле агачтан, мәсәлән, кызыл агачтан ярып алынган бик юка пластинка; матур төс бирү өчен столяр әйберләр өстенә ябыштырыла; 2. һәртөрле агачтан ярып алынган юка пластинкаларны бер-берсе өстенә ябыштырып ясалган табаклы такта).

**ФАНЕ'РНЫЙ** — 1. фанердан ясалган, фанер...; *фанерный ящик* — фанердан ясалган ящик; *фанерная доска* — фанер такта; 2. фанер...-ы; *фанерный завод* — фанер заводы.

**ФАНЕРО'ВЩИК** *м. спец.* — к. фанерщик.

**ФАНЕ'РОЧНЫЙ** *спец.* — фанердан әйберләр ясый торган; *фанерочная мастерская* — фанердан әйберләр ясый торган мастерской.

**ФАНЕ'РЩИК** *м. спец.* — фанердан әйберләр ясаучы.

**ФА'НЗА'** I *ж.* — фанза (ефәк тукыма).

**ФА'НЗА'** II *ж.* — фанза (кытай крестьяннарының өе).

**ФАНТ** *м.* — фант (1. җирәбәгә салынган әйберләрдән кемнең әйбере килеп чыкса, шул кеше башкалар кушкан берәр эшне башкарудан гыйбарәт булган уен; 2. шул уенда катнашучыларның һәркайсыннан җирәбәгә салу өчен алынган әйбер; 3. шул уенда җирәбәсе чыккан катнашучыга кушыла торган эш, мәсәлән, җырлау, бию һ. б.).

**ФАНТАЗЁР** *м.*, **ФАНТАЗЁРКА** *ж.* — фантазёр, хыялланучы, хыялга бирелүче, булмас хыяллар белән мавыгып йөрүче.

**ФАНТАЗИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. хыяллану, хыялга бирелү, буш хыялга бату, буш хыяллар белән мавыгу; 2. *неодобр. (выдумывать)* юк нәрсәләр уйлап чыгару; 3. *муз. редко* алдан хәзерләнмичә берәр көй чыгарып уйнау.

**ФАНТА'ЗИЯ** *ж.* — 1. *только ед.* фантазия, хыял; *у этого писателя богатая фантазия* — бу язучының фантазиясе бик бай; 2. *(выдумка, ложь)* ялган, уйдырма, буш хыял; 3. *разг. (причуда, прихоть)* фантазия, сәер теләк; 4. фантазия (а. *лит.* кайбер фантастик эчтәлекле әдәби әсәрләрнең аңлатмасы; б. *муз.* кайбер музыкаль әсәрләрнең исеме).

**ФАНТАСМАГОРИ'ЧЕСКИЙ** *книж. спец.* — фантасмагорик; *фантасмагорический бред* — фантасмагорик саташу.

**ФАНТАСМАГО'РИЯ** *ж.* — фантасмагория (1. *книж.* саташканда күз алдына килә торган нәрсәләр, сәер күренешләр; 2. *перен. разг.* юк-бар нәрсә, мөмкин булмаган нәрсә; 3. *спец.* төрле оптик җайланмалар ярдәмендә күрсәтелә торган гаҗәеп күренешләр).

**ФАНТА'СТ** *м. книж.* — фантаст (1. фантазиясе көчле кеше; 2. үз хыялларын тормышка ашыруга нык бирелеп тырышучы кеше).

**ФАНТА'СТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.* — хыялый нәрсә, хыял, фантастика.

**ФАНТАСТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. фантастик, гаҗәеп, әкәмәт, тылсымлы; *фантастический вид* — фантастик кыяфәт; 2. хыялый, булуы мөмкин булмаган, кеше ышанмаслык, уйдырма, ялган, фантастик; *фантастические*

*данные*—уйдырма (фантастик) мәгълүматлар; *фантастические слухи* — ялган хәбәрләр; 3. гамәлгә ашмый торган; акылга сыймый торган; *фантастический проект* — гамәлгә ашмый торган (фантастик) проект.

**ФАНТАСТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. мөмкин булмаганлык; 2. кеше ышанмаслык булу, акылга сыймаслык булу, гамәлгә ашмый торган булу.

**ФАНТАСТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. фантастический 2, 3.

**ФАНТО'М** *м.* — фантом (1. *книж.* өрәк, бар булып күренгән юк нәрсә, күзгә күренгән нәрсә, гаҗәеп күренеш; 2. *спец.* кеше яки хайван гәүдәсенең үзе зурлыгында итеп ясалган моделе — музейларда һ. б.).

**ФАНТО'Ш** *м. театр.* — к. марионетка 1.

**ФАНФА'РА** *ж. муз.* — фанфара (1. тынлы музыка коралларында уйнала торган тантаналы яки хәрби характердагы музыкаль фраза; 2. *воен.* трубада уйнала торган кыска гына хәрби сигнал; 3. *перен. разг.* шундый сигнал бирә торган труба — тынлы оркестр коралы). ◇ **Трубить в фанфары** *ирон. перен.* — тавыш куптару, тавыш чыгару, гауга куптару.

**ФАНФАРИ'СТ** *м. муз. воен.* — фанфара уйнаучы, фанфарачы.

**ФАНФА'РНЫЙ** *муз.* — фанфара...-ы; *фанфарные звуки* — фанфара тавышлары.

**ФАНФАРО'Н** *м. пренебр.* — мактанчык, шапырынучы.

**ФАНФАРОН(И)А'ДА** *ж. мн.* нет, *пренебр.* — мактанчыклык, шапырынучылык, мактанчыкларча кылану, шапырынучыларча кылану.

**ФАНФАРО'НИТЬ** *несов. разг. пренебр.* — мактану, шапырыну.

**ФАНФАРО'НСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. пренебр.* — к. фанфаронмада.

**ФА'РА** *ж.* — фара (автомобильнең, паровозның һ. б. алгы фонаре).

**ФАРАО'Н** *м.* — фиргавен (1. *истор.* борынгы Мисыр патшасының титулы; 2. *дореввол. простореч. презрит.* патша Россиясендә полицейскийларга, городовойларга карата нәфрәт белән әйтелгән сүз).

**ФАРАО'НОВСКИЙ** — фиргавен...-ы; *фараоновский дворец* — фиргавен сарае.

**ФАРВА'ТЕР** *м.*—фарватер (диңгезләрдә, елгаларда, күлләрдә судноларр йөри алырлык урыннар). ◇ **Плыть (находиться, быть) в фарватере** *кого-чего* или *чьей* **политики** *книж.* — берәр кешенең яки политиканың тәэсирендә булу, шуның юлыннан бару.

**ФАРИНГИ'Т** *м. мн.* нет, *мед.* — фарингит (тамак ялкынсыну авыруы).

**ФАРИСЕ'Й** *м.* — 1. *религ. истор.* фарисей (борынгы Иудеядә шәһәр байларының дини-политик партиясенең әгъзасы); 2. *перен. ритор.* монафыйк, икейөзле кеше, фарисей.

**ФАРИСЕ'ЙКА** *ж.* — к. фарисей 2.

**ФАРИСЕ'ЙСКИЙ** — 1. *истор. религ.* фарисейлар...-ы; *фарисейская секта* — фарисейлар мәзһәбе; 2. *ритор.* монафыйк, монафыйклык белән..., монафыйкларча, фарисейларча, икейөзле; *фарисейская улыбка* — монафыйкларча елмаю.

**ФАРИСЕ'ЙСТВО** *ср. мн.* нет — 1. *истор. религ.* фарисейлар тәгълиматы; 2. *ритор.* монафыйклык, икейөзлелек, фарисейлык.

**ФАРМАЗО'Н** *м. простореч. устар.* — 1. к. масон; 2. хөр фикерле кеше.

**ФАРМАКОГНО'ЗИЯ** *ж. мн.* нет — фармакогнозия (дару ясауга китә торган матдәләрне өйрәнә торган фән).

**ФАРМАКО'ЛОГ** *м.* — фармаколог (фармокология белгече).

**ФАРМАКОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — фармакология (даруларның организмга тәэсир итүен тикшерә торган фән).

**ФАРМАКОПЕ'Я** *ж. мн.* нет, *спец.* — фармакопея (дару ясаучылар өчен кулланма; аптекаларда дарулык әйберләр исемлеге).

**ФАРМАКОХИ'МИЯ** *ж. мн.* нет — фармакохимия (даруларның химик үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән).

**ФАРМАЦЕ'ВТ** *м.* — фармацевт (дару ясаучы белгеч).

**ФАРМАЦЕ'ВТИКА** *ж. мн.* нет — фармацевтика (даруларны әзерләү, саклау һ. б. турындагы фән).

**ФАРМАЦЕВТИ'ЧЕСКИЙ** — фармацевтик, фармецевтика...-ы, фармацевтлар хәзерли торган; *фармацевтическая школа* — фармацевтлар хәзерли торган мәктәп.

**ФАРМАЦИ'Я** *ж. мн.* нет — к. фармацевтика.

**ФАРС** *м.* — фарс (1. *лит. театр.* җиңел, күп вакытта сай, әдәпсез, мәгънәсез эчтәлекле пьеса; 2. *разг. устар.* әдәпсез тупас шаярту, шамакайларча кыланыш, әдәпсез кыланыш).

**ФАРСЁР** *м. разг. устар.* — шамакай.

**ФА'РСОВЫЙ** *лит. театр.* — фарс характериндагы, фарс характерында язылган *фарсовая пьеса* — фарс характерында язылган пьеса.

**ФАРТ** *м. мн.* нет — 1. *простореч. вульг.* *(риск)* тәвәккәллек, фарт; 2. *(удача)* уңыш.

**ФА'РТИНГ** *м.* — фартинг (Англиядә бронзадан сугылган вак акча.)

**ФАРТИ'ТЬ** *несов. безл. простореч. вульг.* — җай килеп тору, бәрсе улау.

**ФАРТО'ВЫЙ** *простореч. вульг.* — уңышлы, һәр эше җиңел үтә торган, һәр эшендә җай килеп тора торган.

**ФА'РТУК** *м.* — 1. алъяпкыч; 2. *спец.* чехол, (покрышка) япма, капкач.

**ФА'РТУЧНЫЙ** — алъяпкыч...-ы, алъяпкычлык; *фартучный материал* — алъяпкычлык материал.

**ФАРФО'Р** *м.* — фарфор (1. савыт-саба ясауга китә торган ак балчык; 2. шундый балчыктан ясалган әйберләр).

**ФАРФО'РОВЫЙ** — 1. фарфор...-ы; *фарфоровое производство* — фарфор производствосы; 2. фарфор..., фарфордан ясалган; *фарфоровая посуда* — фарфордан ясалган савыт-саба.

**ФАРШ** *м. кулин.* — фарш (вак итеп тапаган ит яки яшелчә).

**ФАРШИРОВА'ТЬ** *несов. кулин.*— фаршлау, фарш салу, эченә тапалган ит, яшелчә тутыру.

**ФАРШИРОВА'ТЬСЯ** *несов. кулин. страд.*— фаршлану, фарш салыну, эченә тапалган ит, яшелчә тутырылу.

**ФАС** *м. книж.*— 1. алгы як, алдан күренеш (берәр нәрсәнең алгы ягы); 2. *воен.* фас (крепость коймасының яки кырдагы хәрби ныгытманың билгеле бер юнәлештә генә ату өчен хезмәт итә торган аерым бер торыгы).

**ФАСА'Д** *м.*— фасад, алгы як (бинаның алгы ягы).

**ФАСА'ДНЫЙ** — фасад...-ы; алгы...-ы; *фасадная сторона здания* — бинаның фасад ягы, бинаның алгы ягы.

**ФАСЕ'Т** *м.*, **ФАСЕ'ТКА** *ж.*— фасет (1. *спец.* берәр нәрсәнең, мәсәлән, клишенең, көзге пыяласының кыекланып төшкән чите; 2. *спец.* шомартылган ташның, хрустальның кырые; 3. *зоол.* кайбер хәшәрәтләрдә була торган катлаулы күзне тәшкил итүче һәрбер аерым күзнең мөгез пәрдәсе).

**ФАСЕ'ТОЧНЫЙ** и **ФАСЕ'ТЧАТЫЙ**: фасеточный глаз *зоол.*— фасет күз (кайбер хәшәрәтләрдә була торган катлаулы күз).

**ФА'СКА** *ж. спец.*— фаска (пычак, балта һ. б. йөзенең чарланган ягы).

**ФАСОВА'ТЬ** *несов. торг.*— фасовать итү, алдан үлчәп-төреп кую.

**ФАСОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. торг.*— фасовать ителү, алдан үлчәп-төреп куелу.

**ФАСО'ВОЧНЫЙ** *спец.*— үлчәп-төрү...-ы; *фасовочная машина* — үлчәп-төрү машинасы.

**ФАСО'ВЩИК** *м.*, **ФАСО'ВЩИЦА** *ж. торг.*— алдан үлчәп-төреп куючы, фасовать итүче.

**ФАСО'ЛЬ** *ж. мн.* нет — фасоль, төрек борчагы (үсемлек).

**ФАСО'Н** *м.*— фасон (1. киемнең киселеш формасы; 2. кайбер нәрсәләрнең тышкы формасы). ◇ **Это надо делать таким фасоном** *перен. разг.*— моны шулай иттереп эшләргә кирәк. **Болезни явились небывалого фасона** (Маяковский) *перен. разг.*— белмәгән-ишетмәгән әллә нинди авырулар килеп чыкты. **Держать фасон** *простореч.*— эреләнү, кәпрәю, масаю. **Не фасон** *простореч.* — ярамый, бармый, батмый; *так поступать — не фасон* — болай эшләү ярамый.

**ФАСО'НИСТЫЙ** — 1. *спец.* к. фасонный; 2. *простореч. ирон.* фасонлы, көяз, купшы; *фасонистый паренёк* — фасонлы (көяз) егет; *фасонистый костюм* — купшы костюм.

**ФАСО'ННЫЙ** *тех.*— билгеле бер фасонлы, билгеле бер калыпка салып ясалган, берәр төрле үрнәк, шаблон буенча ясалган; *фасонные трубы* — билгеле бер фасонлы торбалар.

**ФА'СЦИЯ** *ж. анат.*— фасция (мускул тышчасы).

**ФАТ** *м.*— коры куык, кием калыбы (купшы киенеп кыланчыкланып йөрергә яратучы).

**ФАТА'** *ж.*— фата, бөркәнчек (битне-башны каплар өчен үтә күренмәле материядән ясалган пәрдә).

**ФАТАЛИ'ЗМ** *м.*— фатализм, тәкъдиргә ышану, язмышка ышану.

**ФАТАЛИ'СТ** *м. книж.*— фаталист, тәкъдиргә ышанучы, язмышка ышанучы.

**ФАТАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** — фаталистик, фаталистларча...; *фаталистические взгляды* — фаталистик карашлар.

**ФАТАЛИСТИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. фаталистический.

**ФАТАЛИ'СТКА** *ж.*— к. фаталист.

**ФАТА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— котылгысыз булу, котылгысызлык, тәкъдирдә язылган булу.

**ФАТА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— котылгысыз, котылып калып булмый торган, тәкъдирдә язылган, башка төшкән.

**ФА'ТА-МОРГА'НА** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. мираж.

**ФАТОВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— купшылык, көязлек, көязләнергә ярату.

**ФАТОВА'ТЫЙ** — купшылыкны яратучан, көязләнергә яратучан; *фатоватый юноша* — купшылыкны яратучан егет.

**ФАТОВСТВО'** *ср. мн.* нет — артык көязләнергә ярату, артык көяз булу, кием калыбы булып йөрү, коры куык булу.

**ФА'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.*— к. фатовство.

**ФА'ТУМ** *м. мн.* нет, *книж.*— язмыш, тәкъдир.

**ФАТЮ'Й** *м. простореч. презрит.*— к. фетюк.

**ФА'УНА** *ж. мн.* нет, *книж.*— фауна (хайваннар дөньясы, билгеле бер өлкәгә яки геологик дәвергә хас булган хайваннарның һәммәсе).

**ФАЦЕ'Т** — к. фасет.

**ФАШИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — к. фашизировать.

**ФАШИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— фашистлаштыру (фашизм режимын урнаштыру).

**ФАШИЗИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов.* фашистлашу, фашист булу; 2. *несов. страд.* фашистлаштырылу.

**ФАШИ'ЗМ** *м. только ед. полит.*— фашизм (империалистик буржуазиянең шәфкатьсез террор һәм йөгәнсез агрессия юлы белән чит илләрне яулап алуга, демократияне юк итүгә юнәлдерелгән иң реакцион, ачыктан-ачык террорчылык диктатурасының бер формасы).

**ФАШИ'НА** *ж. спец.*— фашина, чыбыклар бәйләме, чыбыклар көлтәсе (юл һәм буалар ясаганда туфрак өемен ныгыту өчен кулланыла).

**ФАШИ'ННИК** *м. мн.* нет, *спец.*— вак куаклык (фашина ясауга китә торган вак куаклык).

**ФАШИ'ННЫЙ** *спец.*— 1. фашина...-ы, фашина салу...-ы; *фашинные работы* — фашина салу эшләре; 2. фашина салып ясалган; *фашинная дамба* — фашина салып ясалган дамба.

**ФАШИ'СТ** *м.*, **ФАШИ'СТКА** *ж.*— фашист (фашизм тарафдары).

**ФАЭТО'Н** *м.*— фаэтон (1. өсте ачылмалы көймәле коляска; 2. *зоол.* бик тиз оча торган тропик диңгез кошы; 3. өсте ачык җиңел автомобиль).

**ФАЯ'НС** *м.* *мн.* нет — фаянс, керәч (1. яхшы сортлы балчыкка гипс һ. б. катыштырып ясалган ак төстәге масса; 2. шундый массадан ясалган чынаяк әйберләр).

**ФАЯ'НСОВЫЙ** — фаянс..., фаянстан ясалган; *фаянсовая посуда* — фаянс(тан ясалган) савыт-саба.

**ФЕВРА'ЛЬ** *м.*— февраль (елның икенче ае).

**ФЕВРА'ЛЬСКИЙ** — февраль...-ы; *февральская революция* — февраль революциясе (1917 елның 27 февралендә Россиядә булган буржуаз-демократик революция).

**ФЕДЕРАЛИ'ЗМ** *м.* *мн.* нет — федерализм (1. *полит.* федерация принципларына нигезләнгән дәүләт төзелеше яки берәр нәрсәнең федерациягә нигезләнгән структурасы; 2. *полит.* шундый төзелеш урнаштырырга теләгән политик агым).

**ФЕДЕРАЛИ'СТ** *м.*, **ФЕДЕРАЛИ'СТКА** *ж.* *полит.*— федералист, федерализм тарафдары.

**ФЕДЕРАЛИ'СТСКИЙ** *полит.*— федералистик; *федералистские взгляды* — федералистик карашлар.

**ФЕДЕРА'ЛЬНЫЙ** *полит.*— к. федеративный.

**ФЕДЕРА'Т** *м.* *истор.*— федерат (1. 1879 елдагы француз буржуаз революциясе дәверендә милли гвардиянең ирекле сугышчысы; 2. Париж коммунасы дәверендә милли гвардиягә катнашучы).

**ФЕДЕРАТИ'ВНЫЙ** *книж.*— федератив; *Российская Советская Федеративная Социалистическая Республика* (РСФСР)— Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы (РСФСР).

**ФЕДЕРА'ЦИЯ** *ж.*— федерация (1. *полит.* мөстәкыйльлекләрен саклаган дәүләтләрнең берләшүе нигезендә төзелгән яңа бер дәүләт; 2. *книж.* җәмгыятьләр яки оешмалар союзы); *Всемирная федерация демократической молодежи* — бөтендөнья демократик яшьләр федерациясе.

**ФЕЕРИ'ЧЕСКИЙ**, **ФЕЕРИ'ЧНЫЙ** *книж.*— экияттәгечә..., сихерле, тылсымлы, искиткеч; *феерический блеск луны* — айның экияттәгечә (сихерле) ялтыравы.

**ФЕЕ'РИЯ** *ж.*— феерия (1. гадәттән тыш матур сәхнә җиһазлары таләп итә торган экият сюжетлы сәхнә әсәре; 2. *перен.* *книж.* искиткеч матур күренеш, гаҗәеп матур күренеш, экияттәгечә матур күренеш, сихерле күренеш; *феерия лунной ночи на море* — айлы төннең диңгез өстендә экияттәгечә матур булуы.

**ФЕЙЕРБАХИА'НЕЦ** *м.* *филос.*— фейербахчы (Фейербах тәгълиматының тарафдары).

**ФЕЙЕРБАХИА'НСКИЙ** — фейербахчылык...-ы, фейербахчыларча, фейербахчылар...-ы; *фейербахианские взгляды* — фейербахчылык карашлары.

**ФЕЙЕРБАХИА'НСТВО** *ср.* *мн.* нет, *филос.*— фейербахчылык (немец философы материалист Л. Фейербахның философик тәгълиматы).

**ФЕЙЕРВЕ'РК** *м.*— 1. фейерверк (а. тиз кабынып китүчән махсус катнашмаларны яндырудан хасил була торган төрле төстәге декоратив утлар; б. шундый утлар яндырыла торган тамаша уены); 2. *перен.* ташкын; *фейерверк слов* — сүзләр ташкыны.

**ФЕЙЕРВЕ'РКЕР** *м.* *воен.* *доревол.*— фейерверкер (артиллерия унтер-офицеры).

**ФЕКА'ЛИЯ** *ж.* *мн.* нет, *спец.*— тизәк.

**ФЕЛЛА'ХИ** *мн.* (*ед.* феллах)— феллах (гарәп илләрендә — игенче, крестьян).

**ФЕЛЬДМА'РШАЛ** *м.*— фельдмаршал (революциягә кадәр Россиядә һәм кайбер чит илләрдә иң югары хәрби чин).

**ФЕЛЬДМА'РШАЛЬСКИЙ** *воен.* *доревол.*— фельдмаршал...-ы; *фельдмаршальский жезл* — фельдмаршал таягы.

**ФЕЛЬДМА'РШАЛЬСТВО** *ср.* *мн.* нет, *воен.* *доревол.*— фельдмаршал званиесе, фельдмаршаллык.

**ФЕЛЬДФЕ'БЕЛЬ** *м.* *воен.* *доревол.*— фельдфебель (патша армиясендә рота командирының эчке тәртипне саклауда һәм хуҗалык эшләрен башкаруда ярдәмчесе, өлкән унтер-офицер).

**ФЕЛЬДФЕ'БЕЛЬСКИЙ** *воен.* *доревол.*— 1. фельдфебель...-ы; *фельдфебельская должность* — фельдфебель вазифасы; 2. *перен.* *публиц.* фельдфебельләрчә, бик тупас; *фельдфебельские замашки* — фельдфебельләрчә кылану.

**ФЕ'ЛЬДШЕР** *м.*, **ФЕЛЬДШЕРИ'ЦА** *ж.*— фельдшер (врач ярдәмчесе).

**ФЕ'ЛЬДШЕРСКИЙ** — фельдшер...-ы, фельдшерлар...-ы; *фельдшерские курсы* — фельдшерлар курсы.

**ФЕЛЬДЪЕ'ГЕРСКИЙ** — фельдъегер...-ы; *фельдъегерская связь* — фельдъегер элемтәсе.

**ФЕЛЬДЪЕ'ГЕРЬ** *м.*— фельдъегер (хөкүмәт курьеры яки хәрби курьер).

**ФЕЛЬЕТО'Н** *м.*— фельетон (тормыштагы теге яки бу кимчелекләрдән ачы көлеп язылган сатирик эчтәлекле газета мәкаләсе).

**ФЕЛЬЕТОНИ'СТ** *м.*, **ФЕЛЬЕТОНИ'СТКА** *ж.*— фельетончы, фельетон язучы.

**ФЕЛЬЕТО'ННЫЙ** — фельетон...-ы; фельетонга хас; *фельетонный стиль* — фельетонга хас стиль, фельетон стиле.

**ФЕЛЮ'ГА** *ж.* *мор.*— фелюга (Урта һәм Кара диңгезләрдә артык зур булмаган җилкәнле судно).

**ФЕМИ'ДА** *ж.* *книж.* *ритор.*— 1. фемида (борынгы грек мифологиясендә гадел хөкем алласы); 2. гадел хөкем. ◇ **Служитель фемиды** — судья.

**ФЕМИНИЗА'ЦИЯ** *ж.* *мн.* нет, *биол.*— феминизация (печү, хатын-кыз җенес бизләрен күчереп утырту һ. б. нәтиҗәсендә ир кешенең хатын-кызларга хас билгеләрне алуы, мәсәлән, сакал-мыек үсмәү).

**ФЕМИНИ'ЗМ** *м. полит.*— феминизм (капиталистик илләрдә хатын-кызларга формаль яктан тигез хокук бирүне максат итеп куйган буржуаз-политик хәрәкәт).

**ФЕМИНИ'СТ** *м.*, **ФЕМИНИ'СТКА** *ж. полит.*— феминист (феминизм тарафдары).

**ФЕМИНИ'СТСКИЙ** — феминистик; *феминистские взгляды* — феминистик карашлар.

**ФЁН** *м. мн.* нет — 1. *метеор.* жылы, коры җил (таулы илләрдә була); 2. *спец.* электрик чәч киптергеч.

**ФЕНАЦЕТИ'Н** *м. апт.*— фенацетин (тән эсселеген киметү өчен һәм баш авыртудан бирелә торган дару).

**ФЕ'НДРИК** *м.*— 1. *воен. дореврол.* фендрик (яшь офицер, прапорщик); 2. *разг. фам. пренебр.* көяз егет, купшы егет, тәти егет.

**ФЕ'НИКС** *м.*— феникс (борынгы грек мифологиясендә үзен-үзе яндырып көленнән яңадан барлыкка килү сәләтенә ия булган кош; даими рәвештә яңарып тору символы).

**ФЕНО'Л** *хим.*— фенол (карбол кислотасы).

**ФЕНО'ЛОВЫЙ** — фенол...-ы; *феноловые смолы* — фенол сумалалары.

**ФЕНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *биол.*— фенологик; *фенологические явления* — фенологик күренешләр.

**ФЕНОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — фенология (үсемлекләр һәм хайваннар тормышындагы күренешләрнең периодиклыгын һәм ул күренешләрнең климат шартларына бәйләнгән булуын өйрәнә торган фән).

**ФЕНО'МЕН** *м.*— феномен (1. *филос. науч.* к. явление 3; 2. идеалистик философиядә: кеше аңында гына яши һәм объектив чынбарлыкны чагылдырмый торган күренеш; 3. *перен.* берәр ягы белән башкалардан аерылып тора торган гадәттән тыш кеше яки күренеш).

**ФЕНОМЕНАЛИ'ЗМ** *м.*— феноменализм (объектив чынбарлыкны инкарь итүче һәм күренешләр аңда гына яши дип танучы реакцион идеалистик юнәлеш).

**ФЕНОМЕНАЛИ'СТ** *м. филос.*— феноменалист, феноменализм тарафдары.

**ФЕНОМЕНАЛИ'СТСКИЙ** *филос.*— феноменалистларга хас, феноменализмга хас; *феноменалистский взгляд* — феноменалистларга хас караш.

**ФЕНОМЕНА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.*— сирәк очрый торган булу, гаҗәплек, искиткеч булу, гаҗәеп күренеш булу.

**ФЕНОМЕНА'ЛЬНЫЙ** — 1. феноменаль, тышкы; *феноменальная сторона явления* — күренешнең тышкы ягы; 2. *перен.* сирәк очрый торган, гаҗәеп, искиткеч; *феноменальный голос* — сирәк очрый торган тавыш.

**ФЕНОМЕНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *филос.*— феноменологик, феноменологиягә хас.

**ФЕНОМЕНОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *филос.*— феноменология (Гегельнең идеалистик философиясендә аңның, рухның үсеше турындагы тәгълимат).

**ФЕО'Д** *м. истор.*— феод, феодал милкендәге җир.

**ФЕОДА'Л** *м. истор.*— феодал (феодализм чорында крестьяннарны эксплуатацияләүче эре җир биләүче).

**ФЕОДАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *истор.*— феодализм (капитализмнан элек булган һәм феодалларның хосусый милекчелегенә, крепостной крестьяннарны эксплуатацияләүгә нигезләнгән иҗтимагый-экономик формация).

**ФЕОДА'ЛЬНЫЙ** *истор.* — 1. феодализм...-ы; *феодальный строй* — феодализм строе; 2. феодал...-ы, феодаллар...-ы; *феодальные нравы* — феодал гадәтләре.

**ФЕ'РЗЕВЫЙ** *шахм.*— ферзь...-ы; ферзь алдындагы...-ы; *ферзевая пешка* — ферзь пешкасы.

**ФЕРЗЬ** *м.*— ферзь (шахмат уенында иң көчле фигура).

**ФЕ'РМА** I *ж.*— ферма (1. *с.-х.* колхозларда һәм совхозларда авыл хуҗалыгының берәр махсус тармагы белән шөгыльләнә торган хуҗалык предприятиесе; *колхозная птицеводческая ферма* — колхозның кошчылык фермасы; *овцеводческая ферма* — сарык үрчетү фермасы; 2. капиталистик илләрдә үз җирендә яки арендага алынган җирдә оештырылган авыл хуҗалыгы предприятиесе).

**ФЕ'РМА** II *ж. тех.*— ферма (төзелеш эшләрендә — корыч яки агач тарәкләрдән, очлары белән бер-беренә нык беркетеп ясалган корылма); *мостовые фермы* — күпер фермалары.

**ФЕРМА'ТА** *ж. муз.*— фермата (нота язуында тавышны, паузаны сузуны күрсәтү өчен нота яки пауза өстенә куела торган махсус билге).

**ФЕРМЕ'НТ** *м. биол. хим.*— фермент (тере күзәнәкләр тарафыннан эшләп чыгарыла һәм организмда төрле химик реакцияләрне тизләтә торган органик матдә).

**ФЕРМЕНТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет. *биол. хим* — ферментация, әчү-күпчү процессы (фермент ярдәмендә бара торган биохимик процесс).

**ФЕРМЕНТИ'РОВАТЬ** *несов. биол. хим.*— ферментация хәлендә булу, әчү, күпчү.

**ФЕ'РМЕР** *м.*— фермер, ферма хуҗасы (капиталистик илләрдә).

**ФЕ'РМЕРСКИЙ** *м.*— фермер...-ы, фермерлар...-ы; *фермерское хозяйство* — фермер хуҗалыгы; *фермерский союз в США* — АКШта фермерлар союзы.

**ФЕ'РМЕРСТВО** *ср. мн.* нет — 1. фермерлык; 2. *собир.* фермерлар.

**ФЕ'РМЕРША** *ж.*— 1. к. фермер; 2. фермер хатыны.

**ФЕРМУА'Р** *м.*— 1. каптырма (муенсада, китапта, альбомда); 2. (асылташлардан ясалган) каптырмалы муенса; 3 *спец.* өтерге (скульптура эшләрендә кулланыла торган махсус өтерге).

**ФЕРНАМБУ'К** *м. бот.*—кызыл сандал (кызыл буяу чыгара торган агач).

**ФЕРНАМБУ'КОВЫЙ** *бот.*— 1. кызыл сандал...-ы; *фернамбуковое дерево* — кызыл сандал агачы; 2. кызыл сандал...; кызыл сандалдан ясалган.

**ФЕРРОСПЛА'В** *м. тех.* — ферросплав (берәр төрле матдәнең тимер катыштырылган эретмәсе).

**ФЕРРОСПЛА'ВНЫЙ** *тех.* — ферросплав...-ы; *ферросплавный завод* — ферросплав заводы.

**ФЕРТ** *м.*— 1. *устар.* ферт („ф" хәрефенең иске атамасы); 2. *простореч. пренебр.* фырт кеше (мактанчык, кәпрәючән кеше). ◇ **Фертом стоять** (смотреть, глядеть и т. п.) — бөерләргә таянып кукраеп карап тору, кукраеп тору.

**ФЕ'РТИК** *м. простореч. пренебр.* — к. ферт 2.

**ФЕРУ'ЛА** *ж. книж.*— ферула (1. *старин.* иске мәктәптә укучыларны учларына сугып җәзалау линейкасы; 2. *только ед.* бик каты һәм интектергеч күзәтү; *находиться под чьей-н. ферулой* — берәүнең бик каты һәм интектергеч күзәтүе астында булу).

**ФЕ'РЯЗЬ** *ж.*— ферязь (русларның озын җиңле, якасыз борынгы өс киеме).

**ФЕС** *м.*, **ФЕ'СКА** *ж.*— фәс (баш киеме).

**ФЕСТИВА'ЛЬ** *м.*— фестиваль (музыка, театр, кино һ. б. өлкәләрдә уңышларны күрсәтү максаты белән вакыт-вакыт үткәрелә торган бәйрәм, күргәзмә; *музыкальный фестиваль* — музыка фестивале; 2. *шутл.* мәҗлес, күңелле бәйрәм).

**ФЕСТО'Н** *м.*— 1. телле-телле (итеп ясалган) кайма (пәрдәдә, итәк читләрендә); 2. фестон (*архит.* ярым түгәрәк формада эшләнгән гирлянда).

**ФЕСТО'НЧАТЫЙ** — каймалы; *фестончатая оборка* — телле-телле итеп ясалган каймалы бала итәк.

**ФЕТИ'РОВАТЬ** *несов. разг. фам. устар.*— тәбрикләү, мәҗлес оештырып тәбрикләү.

**ФЕТИ'Ш** *м.*— фетиш (1. борынгы кабиләләрнең табыну әйбере; 2. *перен.* һичсүзсез сукырларча ышану һәм ияү әйбере).

**ФЕТИШИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж. неодобр.*— к. фетишизм 2.

**ФЕТИШИЗИ'РОВАТЬ** *несов. книж. неодобр.*— фетишлаштыру, фетишка әйләндерү.

**ФЕТИШИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж. неодобр.*— фетишлаштырылу, фетишка әйләндерелү.

**ФЕТИШИ'ЗМ** *м. мн.* нет — фетишизм (1. берәр төрле нәрсәдә яки күренештә акылга сыймаслык серле көчләр күреп, аларны аллалаштыру, шуларга табыну; 2. *перен. книж. неодобр.* сукырларча табыну, сукырларча ышану).

**ФЕТИШИ'СТ** *м.*— 1. фетишист, фетишларга табынучы; 2. *перен. неодобр.* (берәр нәрсәгә) сукырларча табынучан, сукырларча ышанучан кеше.

**ФЕТР** *м. мн.* нет — фетр (эшләпә һ. б. ясауга китә торган иң яхшы сорт юка киез).

**ФЕ'ТРОВЫЙ** — фетр...-ы, фетрдан ясалган; *мягкая фетровая шляпа* — йомшак фетр эшләпә.

**ФЕТЮ'К** *м. простореч. презрит.*—ачык авыз.

**ФЕФЁЛА** *ж. простореч. презрит.*— алпавыт биясе, борчак чүмәләсе (зур гәүдәле шапшак киенгән хатын).

**ФЕХТОВА'ЛЬНЫЙ** — фехтование...-ы; *фехтовальный зал* — фехтование залы.

**ФЕХТОВА'ЛЬЩИК** *м.*— фехтовальщик.

**ФЕХТОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — фехтование (кылыч сугышы, кылыч ярышы).

**ФЕХТОВА'ТЬ** *несов. спорт.* — фехтовать итү (кылыч, рапира һ. б. кулланып) ярышу, сугышу).

**ФЕШЕНЕ'БЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — модалы булу, үтә купшылык (буржуаз җәмгыятьтә).

**ФЕШЕНЕ'БЕЛЬНЫЙ** — модалы, үтә купшы (буржуаз җәмгыятьтә).

**ФЕ'Я** *ж.* — фея (1. *миф.* Көнбатыш Европа әкиятләрендә төрле могҗизалар эшли ала торган сихерче хатын; 2. *поэт.* гүзәл, чибәр, сокландыргыч хатын).

**ФИ** *межд. разг.*— хи; *фи, какой противный* — хи, нинди чирканыч.

**ФИА'КР** *м. загр.*— извозчик.

**ФИА'Л** *м.*— 1. фиал (борынгы грекларда — киң шешәсыман муенлы савыт); 2. *поэт.* кубок (зур бокал формасындагы металл савыт).

**ФИА'ЛКА** *ж.*— миләүшә.

**ФИА'ЛКОВЫЙ** — миләүшә...-ы; *фиалковый запах* — миләүшә исе. ◇ **Фиалковый корень** — ирис тамыры (кипкәч миләүшә исе чыгара, парфюмериядә кулланыла).

**ФИА'СКО** *ср. нескл.*—тулы уңышсызлык; *потерпеть фиаско* — тулы уңышсызлыкка очрау, тулы уңышсызлыкка дучар булу.

**ФИ'БРА** I *ж. книж.*— мускул җепселе. ◇ **Всеми фибрами души** — җаны-тәне белән.

**ФИ'БРА** II *ж. мн.* нет, *тех.* — фибра, катыргы (тыгыз итеп прессланган кәгазь массасы; чемоданнар, тартмалар ясауга китә һәм изоляцион материал булып хезмәт итә).

**ФИБРИ'Н** *м. мн.* нет, *физиол.*— фибрин (кан оешу нәтиҗәсендә барлыкка килгән аксым).

**ФИ'БРОВЫЙ** *тех.*— фибрадан ясалган; *фибровый чемодан* — фибрадан ясалган чемодан.

**ФИБРО'ЗНЫЙ** *анат.*— җепселсыман; *фиброзная соединительная ткань* — җепселсыман тоташтыргыч тукыма.

**ФИБРОЛИ'Т** *м. мн.* нет, *тех.*— фибролит (йомычканы пресслап ясаган төзү материалы — кирпеч).

**ФИБРОЛИ'ТОВЫЙ** — фибролит..., фибролиттан ясалган; *фибролитовая стена* — фибролиттан ясалган стена.

**ФИБРО'МА** *ж. мед.*— фиброма (зарарсыз шеш).

**ФИ'ГА** *ж.*— 1. *бот.* инҗир (агачы һәм җимеше); 2. *разг.* к. кукиш ◇ **Фига с маслом** — к. кукиш.

**ФИГАРО'** *нескл.*— фигаро (хатын-кызлар блузкасының бер төре).

**ФИ'ГЛИ** и **ФИ'ГЛИ-МИ'ГЛИ** *ед.* нет, *разг. фам.*— хәйләләр, шаяртулар; *разные фигли-мигли* — төрле хәйләләр, шаяртулар.

**ФИГЛЯ'Р** *м.*— 1. *разг. устар.* шамакай, мәзәкче, фокуслар күрсәтүче, акробат; 2. *перен. разг. пренебр.*—кыланчык (кыланчыкланып үзенә каратырга тырышучы; 3. *зоол.* фигляр (карчыгалар семьялыгыннан ерткыч кош).

**ФИГЛЯ'РИТЬ** *несов. разг.*— (әллә ниләр) кылану, шамакайлану.

**ФИГЛЯ'РНИЧАТЬ** *несов. разг.*— к. фиглярить.

**ФИГЛЯ'РСКИЙ** *разг.*— шамакай...-ы; шамакайларча...; *фиглярская выходка* — шамакайларча кылану.

**ФИГЛЯ'РСТВО** *ср. разг.*— шамакайлык.

**ФИ'ГОВЫЙ** — инжир...-ы; *фиговые листья* — инжир яфраклары; *фиговое дерево* — инжир агачы.◇ **Фиговый листок** — фига яфрагы (1. скульптурада ялангач кеше сыннарының җенес әгъзаларын каплап куйган яфрак сурәте; 2. *перен.* икейөзләләнеп оятсыз, намуссыз эшләрне яшереп калу).

**ФИГУ'РА** *ж.*— 1. фигура (а. геометрик җисем, мәсәлән, өчпочмак, параллелограмм, конус һ. б.; б. *тип.* китапларда чертежлар, рәсемнәр, схемалар атамасы; в. танецта, гимнастикада, фехтованиедә һ. б. мәгълүм хәрәкәтләр; г. *лит.* сөйләмнең тәэсирен көчәйтә торган стилистик алым; д. *живоп.* кешенең яки хайванның сыны, скульптурасы; е. шахмат уенында — король, ферзь, фил, ат, ладья); 2. сын, гәүдә; *крупная фигура* — зур гәүдә; 3. *перен.* кеше; *подозрительная фигура* — шикле кеше; 4. зур (урындагы) кеше; *в свое время он был важной фигурой* — үз вакытында ул зур кеше иде.

**ФИГУРА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— кинаялелек, кинаяле булу, образлылык.

**ФИГУРА'ЛЬНЫЙ** *книж.*— кинаяле, образлы; *фигуральное выражение* — кинаяле әйтем, образлы әйтем.

**ФИГУРА'НТ** *м.*, **ФИГУРА'НТКА** *ж.*—фигурант (1. *театр.* балетта группага катнашып кына биюче; 2. *театр.* спектакльдә сүзсез катнашучы артист, статист; 3. *спец.* төрле фигуралы татлы ашамлыклар хәзерләүче кондитер).

**ФИГУРИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— 1. катнашу, булу, булып тору, очрау, куелу; *фигурировать на суде в качестве свидетеля* — судта шаһит булып катнашу; 2. очрау; *этот образ фигурирует в ряде произведений писателя* — бу образ язучының күп кенә әсәрләрендә очрый; 3. куелу; *этот вопрос неоднократно фигурировал в повестке дня* — бу мәсьәлә берничә тапкыр көн тәртибенә куелды.

**ФИГУРИ'СТ** *м.*, **ФИГУРИ'СТКА** *ж. спорт.*— фигурист, фигурачы (тимераякта шуганда төрле фигуралар ясаучы спортсмен).

**ФИГУ'РИСТЫЙ** *разг.*— образлы, фигуралы, образларга (фигураларга) бай; *фигуристый слог* — образлы стиль.

**ФИГУ'РНЫЙ** — 1. берәр геометрик җисемгә охшатып ясалган, бизәкле; *фигурная резьба* — берәр геометрик фигурага охшатып кисеп ясалган рәсем (берәр геометрик фигурага охшатып агачка, сөяккә сырлап ясалган бизәк); 2. төрле фигуралар ясап...; *фигурное катанье на коньках* — төрле фигуралар ясап тимераякта шуу; 3. *простореч.* матур гәүдәле; *и дурень, да фигурен*— ахмак булса да матур гәүдәле.

**ФИГУРЯ'ТЬ** *несов. простореч.*— кылану, үзен күрсәтергә маташу.

**ФИДЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — фидеизм (философиядә дингә ышануны белемнән, фәннән өстен куя торган реакцион идеалистик агым).

**ФИДЕИ'СТ** *м.*, **ФИДЕИ'СТКА** *ж. книж.*— фидеист, фидеизм тарафдары.

**ФИДЕИСТИ'ЧЕСКИЙ** — фидеистик; *фидеистические взгляды* — фидеистик карашлар.

**ФИ'ДЕР** *м. тех.*— фидер (1. чи материалны эшкәртү өчен машинага биреп тора торган корылма; 2. энергияне электростанциядән төп куллану урыннарына җибәрү үткәргече).

**ФИЕ'ЛЬД** *м. геогр.*— фиельд (Норвегиядә, Төньяк Америкада таулар һәм чокырлар чиратлашуыннан гыйбарәт биек калкулык).

**ФИ'ЖМЫ** *ед. нет* — 1. фижма (18—19 гасырларда хатын-кызларның гәүдәсен тулы итеп күрсәтү өчен юбка итәге астына куела торган кыршау); 2. шундый кыршаулы юбка.

**ФИЗИА'ТР** *м. мед.*— к. физиотерапевт.

**ФИЗИАТРИ'ЧЕСКИЙ** *мед.*— к. физиотерапевтический.

**ФИЗИАТРИ'Я** *ж. мн.* нет — к. физиотерапия.

**ФИ'ЗИК** *м.*— физик (1. физика белгечегалим; 2. физика укытучысы; 3. югары уку йортында физика бүлеге студенты).

**ФИ'ЗИКА** *ж.*— 1. физика (материянең үзлекләре һәм төзелеше, аның хәрәкәт итүе һәм үзгәреше, органик булмаган табигать күренешләренең гомуми закончалыклары турындагы фән); 2. *простореч.вульг.* (физиономия) йөз, бит.

**ФИ'ЗИКО-ГЕОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — физик география...-ы, физик география буенча...; *физико-географический очерк* — физик география буенча очерк.

**ФИ'ЗИКО-МАТЕМАТИ'ЧЕСКИЙ** — физика-математика...-ы; *физико-математический факультет* — физика-математика факультеты. ◇ **Физико-химический** — физик-химик; *физико-химический анализ* — физик-химик анализ.

**ФИЗИОГНО'МИКА** *ж. мн.* нет, *спец. псих.*— физиогномика (йөзнең хәрәкәтләренә, мимикасына карап кешенең эчке халәтен билгеләү сәнгате).

**ФИЗИОКРА'ТЫ** *ед. нет, экон.*—физиократлар (18 йөздә килеп чыгып, тик игенчелек кенә кыйммәтне барлыкка китерә торган житештерүче хезмәт дип исәпләгән һәм капиталистик фермерлар идеологиясен чагылдырган политик-экономик тәгълимат тарафдарлары).

**ФИЗИО'ЛОГ** *м.*— физиолог, физиология белгече.

**ФИЗИОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — физиологик; *физиологические процессы* — физиологик процесслар.

**ФИЗИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — физиология (1. организмның функцияләре турындагы фән; *физиология человека* — кеше физиологиясе; *физиология растений* — үсемлекләр физиологиясе; 2. шул функцияләрнең үзләре һәм алар белән идарә итүче законнар).

**ФИЗИОНО'МИКА** *ж. мн.* нет, *спец. псих.* — к. физиогномика.

**ФИЗИОНОМИ'СТ** *м.* — физиономист (йөзнең хәрәкәтләренә, мимикасына карап кешенең эчке халәтен билгеләүче).

**ФИЗИОНО'МИЯ** *ж.* — 1. йөз, бит; чырай; 2. бәндә, кеше; *в комнату вошла какая-то мрачная физиономия* — бүлмәгә әллә нинди бер караңгы чырайлы бәндә килеп керде; 3. *перен. только. ед.* күренеш; *физиономия города* — шәһәрнең күренеше.

**ФИЗИОТЕРАПЕ'ВТ** *м. спец.* — физиотерапевт (физиотерапия врачы, физиотерапия белгече).

**ФИЗИОТЕРАПЕВТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — физиотерапевтика ...-ы; физиотерапевтик; *физиотерапевтический кабинет* — физиотерапевтика кабинеты; *физиотерапевтическое лечение* — физиотерапевтик дәвалау.

**ФИЗИОТЕРАПИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.* — физиотерапия (физик чаралар белән, ягъни хәрәкәт, җылылык, су һ. б. белән дәвалау).

**ФИЗИ'ЧЕСКИЙ** — 1. физика ...-ы; *физический кабинет* — физика кабинеты; 2. физик; *физические опыты* — физик тәҗрибәләр; *физическая химия* — физик химия; *физические свойства тел* — җисемнәрнең физик үзлеге; 3. физик (мускул көче, кул көче белән эшләнә торган); *физическая работа* — физик эш (кул көче белән эшләнә торган эш); *физическое воспитание* — физик тәрбия; 4. җенси; *физическая близость* — җенси бәйләнеш. ◇ **Физические методы лечения** — к. физиотерапия. **Физическая культура** — к. физкультура. **Физическое лицо** — к. лицо.

**ФИЗКУЛЬТУ'РА** (физическая культура) *ж. мн.* нет — физкультура (тән тәрбиясе, тән тәрбиясенә бәйләнешле хәрәкәтләр, спорт уеннары).

**ФИЗКУЛЬТУ'РНИК** *м.*, **ФИЗКУЛЬТУ'РНИЦА** *ж.* — физкультурник, физкультурачы.

**ФИЗКУЛЬТУ'РНЫЙ** — 1. физкультура ...-ы; *физкультурные движения* — физкультура хәрәкәтләре; 2. физкультурниклар ...-ы; *физкультурный парад* — физкультурниклар парады.

**ФИЗМА'Т** (физико-математический факультет) *м.* — физмат (физика-математика факультеты).

**ФИКСА'Ж** *м.* — фиксаж (1. фотокәгазьгә яки пленкага төшерелгән рәсемне ныгыту өчен кулланыла торган химик эремә; 2. *живоп.* к. фиксатив).

**ФИКСАТИ'В** *м. живоп.* — фиксатив (карандаш белән төшерелгән рәсемнәрнең өстенә аларны бозылудан саклау өчен сөртелә торган махсус эремә).

**ФИКСА'ТОР** *м. спец.* — фиксатор (берәр нәрсәне регулирлау, җайга салу приборы).

**ФИКСАТУА'Р** *м.* — фиксатуар (чәч, мыек помадасы).

**ФИКСА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж. спец.* — к. фиксировать.

**ФИКСИ'РОВАТЬ** *несов.* — 1. *книж.* теркәү, беркетү; 2. *книж.* язу, язып алу, язып бару, теркәү; *фиксировать все замечания выступавших* — чыгыш ясаучыларның барлык замечаниеләрен язып алу; 2. *книж.* билгеләү; *фиксировать дни заседаний* — утырыш көннәрен билгеләү; *фиксировать место сбора* — җыела торган урынны билгеләү; 3. *книж.* туплау, (игътибарны) юнәлдерү; *фиксировать внимание на чем-н.* — игътибарны берәр нәрсәгә юнәлдерү, игътибарны берәр нәрсәгә туплау; 4. *фото* фиксаж белән эшкәртү, фиксажлау.

**ФИКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ялганлык.

**ФИКТИ'ВНЫЙ** *книж.* — ялган; *фиктивный документ* — ялган документ.

**ФИ'КУС** *м. бот.* — фикус (1. тропик якта үсә торган мәңге яшел үсемлек; 2. бүлмә гөле).

**ФИ'КЦИЯ** *ж. книж.* — 1. уйдырма, ялган нәрсә, алдау; 2. фикция (хаклыктан, чынбарлыктан ерак булган, ләкин берәр максат белән файдаланыла торган уйдырма теория).

**ФИЛАНТРО'П** *м.*, **ФИЛАНТРО'ПКА** *ж.* — филантроп (филантропия белән шөгыльләнүче).

**ФИЛАНТРОПИ'ЧЕСКИЙ** — филантропик.

**ФИЛАНТРО'ПИЯ** *ж. мн.* нет — филантропия (буржуазиянең ярлыларга „ярдәм" иткән булып, аларның аннарын сыйнфый көрәштән читкә юнәлдерергә, үзен игелекле итеп күрсәтеп, хезмәт ияләрен алдарга маташуының бер чарасы).

**ФИЛАРМОНИ'ЧЕСКИЙ** — 1. филармония ...-ы; *филармонический оркестр* — филармония оркестры; 2. *книж.* музыка сөючеләр ...-ы; *филармоническое общество* — музыка сөючеләр җәмгыяте.

**ФИЛАРМО'НИЯ** *ж. мн.* нет — филармония (концертлар оештыруны һәм музыка пропагандалауны үзенә максат итеп куючы учреждение яки җәмгыять).

**ФИЛАТЕЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — филателизм (почта маркалары, гербовый маркалар, кәгазь акчалар һ. б. коллекциясе җыю).

**ФИЛАТЕЛИ'СТ** *м.*, **ФИЛАТЕЛИ'СТКА** *ж.* — филателист (почта маркалары, гербовый маркалар, кәгазь акчалар һ. б. коллекциясе җыючы).

**ФИЛАТЕЛИ'СТИЧЕСКИЙ, ФИЛАТЕЛИ'СТСКИЙ** — филателистлар ...-ы; *филателистическое общество* — филателистлар җәмгыяте.

**ФИЛАТЕЛИ'Я** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. филателизм.

**ФИЛЕ'** I *ср. нескл. спец.* — филе (челтәрле материягә чигелгән чигеш).

**ФИЛЕ'** II *ср. нескл. спец.* — 1. билдәмә

(сырт итенең урта өлеше); 2. *кулин.* филе (а. сөяксез ит; кылчыксыз балык ите; б. шундый иттән яки балык итеннән хәзерләнгән ашамлык).

**ФИЛЕ'Й** *м. мн.* нет, *спец.*— к. филе II, 1.

**ФИЛЕ'ЙНЫЙ** I *спец.*— челтәрле материягә чигелгән; *филейная вышивка* — челтәрле материягә чигелгән чигеш.

**ФИЛЕ'ЙНЫЙ** II *спец*— 1. билдәмә ...-ы; *филейная часть* — билдәмә өлеше; 2. сөяксез ит ...-ы; *филейный кусок* — сөяксез ит кисәге.

**ФИЛЁНКА** *ж.*—филенка (1. *столяр.* ишек рамына, тәрәзә капкачына һ. б. куела торган юка такта яки фанер; 2. *архит.* турыпочмаклы рам рәвешендә биналарның стенасына ясалган бизәк).

**ФИЛЁНОЧНЫЙ** *столяр.*— 1. филенкадан ясалган, юка тактадан (яки фанердан) ясалган; *филеночная дверь* — филенкадан ясалган ишек; 2. филенка эшкәртә торган; *филеночный рубанок* — филенка эшкәртә торган струк.

**ФИЛЁНЧАТЫЙ** — к. филеночный 1.

**ФИЛЕ́Р** *м.*— шымчы (капиталистик илләрдә полиция агенты).

**ФИЛЁРСКИЙ** — шымчы ...-ы; *филёрская профессия* — шымчы кәсебе.

**ФИЛИА'Л** *м.*— филиал, бүлек; *Казанский филиал Академии Наук СССР* — СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы.

**ФИЛИГРА'ННЫЙ** *спец.*— 1. филигран ... (алтын, көмеш һ. б. төр металл чыбыктан үреп ясалган); *филигранные изделия* — филигран әйберләр; 2. *перен.* пөхтә, нәфис; *филигранная работа*—нәфис эш, пөхтә эш.

**ФИЛИГРА'НЬ** *ж. спец.*— филигрань (1. алтын, көмеш яки башка төрле металл чыбыктан үреп ясалган зиннәт әйбере); 2. су билгесе, филигрань (яктыга тотып карагандa кәгазьнең кайбер төрләре эчендә яктырып күренә торган рәсем, тамга).

**ФИ'ЛИН** *м. зоол.*— мәче башлы ябалак, байгыш.

**ФИЛИ'ППИКА** *ж. книж.*— филиппика (берәүгә каршы, аның йөзен фаш итеп ясалган чыгыш).

**ФИЛИ'РОВАТЬ** *несов. муз.*— (башта көчәйтә барып, аннан акрынайта барып) авазны сузу.

**ФИЛИ'СТЕР** *м. презрит.*— филистер (мещаннарча, обывательләрчә тар карашлы, икейөзле кеше).

**ФИЛИ'СТЕРСКИЙ** *презрит.*— филистерларча ..., филистер ...-ы, филистерларга хас; *филистерский взгляд* — филистерларга хас караш.

**ФИЛИ'СТЕРСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. презрит.*— филистерлык, обывательләрчә тар карашлылык.

**ФИ'ЛЛЕР** *м.*— филлер (Венгриядә вак акча).

**ФИЛЛОКСЕ'РА** *ж. зоол.*— филлоксера, йөзем бете (корткыч бөҗәк).

**ФИЛОГЕНЕ'З** *м. биол.*— филогенез (гомумән органик дөньяның яки аның аерым группаларының үсеш процессы); *филогенез растений* — үсемлекләр филогенезы.

**ФИЛОГЕНЕТИ'ЧЕСКИЙ** *биол.*— филогенетик.

**ФИЛОГЕ'НИЯ** *ж. мн.* нет, *биол.*— филогения (1. үсемлекләрнең һәм хайваннарның үсеш закончалыгын тикшерә торган фән; 2. к. филогенез).

**ФИЛОДЕНДРО'Н** *м. бот.*— филодендрон (тропик Америкада үсә торган декоратив үсемлек, агач).

**ФИЛО'ЛОГ** *м.*— филолог (1. филология белгече; 2. филология факультеты студенты).

**ФИЛОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — 1. филология ... -ы; *филологический факультет* — филология факультеты; 2. филологик; *филологический анализ старинной рукописи* — борынгы кульъязмага филологик анализ.

**ФИЛОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — филология (берәр халыкның теле, әдәбияты турындагы фән); *славянская филология* — славян филологиясе.

**ФИЛО'СОФ** *м.*— философ (1. философия белгече, философия белән шөгыльләнүче; 2. *перен. разг.* тормыш авырлыкларына пошынмыйча карауч).

**ФИЛОСОФИ'ЧЕСКИЙ** *устар.*— к. философский.

**ФИЛОСО'ФИЯ** *ж. мн.* нет — философия (1. табигать, кешелек җәмгыяте һәм фикерләү үсешенең гомуми законнары турындагы фән; *материалистическая философия* — материалистик философия; *идеалистическая философия* — идеалистик философия; 2. берәр фәннең нигезен тәшкил иткән теоретик, методологик принциплар; *философия математики* — математиканың нигезен тәшкил иткән теоретик, методологик принциплар; 3. *разг.* коры фәлсәфә, коры сүз боткасы; *к чему твоя философия?*— синең коры фәлсәфәңнең нигә кирәге бар? 4. *устар.* философия (электә өч сыйныфлы духовный семинариянең икенче сыйныфы).

**ФИЛОСО'ФСКИЙ** — 1. философик; *марксистский философский материализм* — марксистик философик материализм; 2. *перен. разг.* философларга хас, философларча..., житди; *философское отношение к жизни* — тормышка философларча карау. ◇ **Философский камень** — серле таш (урта гасырларда, алхимиклар карашынча, һәрбер металлны алтынга әверелдерә һәм барлык авыруларны дәвалый ала торган таш).

**ФИЛОСО'ФСТВОВАНИЕ** *ср.*— 1. *только ед.* к. философствовать; 2. *перен.* фәлсәфә, фәлсәфә сату.

**ФИЛОСО'ФСТВОВАТЬ** *несов.*— 1. философия белән шөгыльләнү, философия белән мавыгу; 2. *перен. разг.* фәлсәфә сату.

**ФИЛЬДЕКО'С** *м. мн.* нет, *спец.*— фильдекос (киҗе-мамыктан эрләнгән ефәксыман җеп).

**ФИЛЬДЕКО'СОВЫЙ** *спец.* — фильдекос..., фильдекостан эшләнгән; *фильдекосовые чулки* — фильдекос оек.

**ФИЛЬДЕПЕ'РС** *м. мн.* нет, *спец.*— фильдеперс (иң яхшы трикотаж киемнәр өчен махсус эшләнгән ефәксыман җеп).

**ФИЛЬДЕПЕ'РСОВЫЙ** *спец.*— фильдеперс..., фильдеперстан эшләнгән; *фильдеперсовые чулки* — фильдеперс оек.

**ФИ'ЛЬКА** *м. простореч. шутл.*— к. филёр.

**ФИ'ЛЬКИН: филькина грамота** — к. грамота II.

**ФИ'ЛЬМ** *м.*— 1. *спец.* фильм (өске катламы яктылык сизүчән, юка, үтә күренмәле пленка; фото һәм кинематографиядә кулланыла); 2. *спец.* кинолента, кино лентасы; 3. *спец.* фильм, кинокартина; *звуковой фильм* — тавышлы фильм; *цветной фильм* — төсле фильм.

**ФИЛЬМОТЕ'КА** *ж. спец.*— фильмотека (махсус бинада тәртипкә салып саклана торган киноленталар архивы).

**ФИ'ЛЬТР** *м.*— фильтр (1. сыекчаларны сөзеп чистарта торган җайланма; *водопроводный фильтр* — водопровод фильтры; 2. *спец.* кайбер нурларны, тавыш һәм электромагнит дулкыннарын үткәрми торган прибор; *световой фильтр* — яктылык фильтры).

**ФИЛЬТРА'Т** *м. спец.*— фильтрат (фильтр аша үткәрелгән сыекча).

**ФИЛЬТРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.*— фильтрация (1. к. фильтровать 1; 2. сыекчаның вак-вак тишекле матдәләр аша саркып үтүе).

**ФИЛЬТРОВА'ЛЬНЫЙ** — фильтр...-ы; *фильтровальная бумага* — фильтр кәгазе.

**ФИЛЬТРОВА'ТЬ** *несов.*— 1. сөзү, фильтрлау, фильтрдан үткәрү, сөзеп чистарту; *фильтровать воду* — суны фильтрдан үткәрү; 2. *перен. разг.* тикшерү, сайлап алу, иләк аша үткәрү; *фильтровать кандидатов* — кандидатларны сайлап алу.

**ФИЛЬТРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. фильтрдан үткәрелү, фильтрлану; 2. тикшерелү, сайлап алыну, иләк аша үткәрелү.

**ФИ'ЛЯ** *м. обл.*— к. простофиля.

**ФИМИА'М** *м. мн.* нет — 1. фимиам (хуш исле сумала, ладан); 2. *книж. поэт.* хуш ис. ◇ **Курить или жечь фимиам** *перен. книж.*— бик нык мактау, күккә күтәреп мактау, ялагайланып мактау, күкләргә күтәрү.

**ФИНА'Л** *м.*— 1. финал, тәгәлләнү, ахыр, азак; *печальный финал* —(эшнең) күңелсез тәгәлләнүе; 2. *финал* (а. *муз.* музыка яки драма әсәренең соңгы өлеше; б. *спорт.* спорт ярышларының иң соңгы хәлиткеч бүлеге; *играть в финале* — финалда уйнау).

**ФИНАЛИ'СТ** *м. спорт.*— финалда катнашучы (спорт ярышларының соңгы матчында катнашучы).

**ФИНА'ЛЬНЫЙ** — ахыргы, соңгы; *финальная часть пьесы* — пьесаның соңгы кисәге; *финальная встреча* — (спорт ярышында) ахыргы очрашу.

**ФИНАНСИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— акча бирү, акча белән тәэмин итү.

**ФИНАНСИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— акча бирелү, акча белән тәэмин ителү.

**ФИНАНСИ'СТ** *м.*, **ФИНАНСИ'СТКА** *ж.*— финансист (1. финанс операцияләрен алып баручы белгеч; 2. финанс фәннәре белән шөгыльләнүче; белгеч; 3. *дореволюц. загр.* банкир, финанс капиталы хуҗасы).

**ФИНА'НСОВЫЙ** — финанс...-ы; *финансовый отдел* — финанс бүлеге.

**ФИНА'НСЫ** *ед.* нет — финанс, акча.

**ФИ'НИК** *м.*— хөрмә (җимеш).

**ФИ'НИКОВЫЙ** — хөрмә ...-ы; *финиковый лист* — хөрмә яфрагы; *финиковая пальма* — хөрмә пальмасы.

**ФИНИНСПЕ'КТОР** *м.* (финансовый инспектор)— фининспектор.

**ФИНИ'ФТЬ** *ж.*— финифть (металл әйберләргә йөгертү һәм фарфорга бизәк төшерү өчен кулланыла торган эмаль — эләә).

**ФИ'НИШ** *м. мн.* нет, *спорт.*—(1. тизлеккә үткәрелә торган спорт ярышының соңгы өлеше; 2. шундый ярышларда килеп туктау урыны).

**ФИ'НИШЕР** *м. тех.*— финишер (юлга бетон җәйгәндә аны тигезләп таптата торган машина).

**ФИНИШИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спорт.*— финишка килү; *финишировать первым* — финишка беренче булып килү.

**ФИ'НИШНЫЙ** *спорт.*— финиш...-ы; *финишная часть дорожки* — юлның финиш өлеше.

**ФИ'НКА** I *ж.*— фин хатын-кызы.

**ФИ'НКА** II *ж.*— финка (1. *разг.* кынына тыгып йөртелә торган юан саплы кыска пычак; 2. муенны һәм колакларны каплар өчен кайтарма кырпуы төшерелә торган бүрек; 3. башлыча Финляндиядә үрчетелә торган ат токымы).

**ФИ'НКА** III *ж.*— к. финна.

**ФИНЛЯ'НДКА** *ж.*— Финляндиядә яшәүче хатын-кыз.

**ФИНЛЯ'НДЦЫ** *ж.*— Финляндиядә яшәүчеләр, финляндиялеләр, Финляндиядә яшәүче халык.

**ФИ'ННА** *ж. зоол.*— финна (хайваннарның мускулларында яки башка органнарында яшәүче тасма суалчан корты).

**ФИННО'З** *м. мед. вет.*— финноз (тасма суалчан кортлары — финналар тудыра торган авыру).

**ФИННО'ЗНЫЙ** *мед. вет.*— финналы, тасма суалчан кортлары булган; *финнозное мясо* — финналы ит.

**ФИННО-УГО'РСКИЙ** — к. угро-финский.

**ФИННО-У'ГРЫ** *мн.* к.— угро-финны.

**ФИ'ННЫ** *мн.* (*ед.* финн)— финнар, фин халкы (Финляндиянең төп халкы).

**ФИНОТДЕ'Л** *м.* (финансовый отдел)— финанс бүлеге.

**ФИНПЛА'Н** *м.* (финансовый план) — финанс планы.

**ФИ'НСКИЙ** — фин...-ы; *финский язык* — фин теле.

**ФИНТИ'ТЬ** *несов. разг. фам.*— 1. хәйлә

ләү, койрык болгау; кылану; 2. *устар.* ялагайлану, тәлинкә тоту.

**ФИНТИФА'НТЫ** *только мн. простореч. фам. устар.*— 1. хәйләле сылтаулар; төрле хәйләләр; 2. вак-төякләр, юк-бар нәрсә, вак-төяк әйберләр.

**ФИНТИФЛЮ'ШКА** *ж. разг. фам. пренебр.*— 1. вак-төяк зиннәт әйберләре; 2. *только мн. перен.*— юк-бар сүз, буш сүз, юк сүз, сафсата.

**ФИНЬШАМПА'НЬ** *м. мн.* нет — финьшампань (коньякның иң яхшы сорты).

**ФИОЛЕ'ТОВЫЙ** — 1. шәмәхә...; *фиолетовый цвет* — шәмәхә төс; 2. миләүшә төсендәге, шәмәхә төстәге; *фиолетовое платье*— шәмәхә төстәге күлмәк.

**ФИО'РД** *м.*— фиорд (бормаланып еракка сузылган биек һәм текә ярлы диңгез култыгы).

**ФИОРИТУ'РА** *ж.*— 1. *муз.* к. колоратура 1; 2. *перен. ирон.* катлаулы тәгъбир, бормалы-сырмалы тәгъбир.

**ФИ'РМА** *ж.*— 1. фирма (капиталистик илләрдә сәүдә яки промышленность предприятиесе); 2. *перен. разг.* сылтау, пәрдә, маска, хәйлә; *под фирмой демократизма* — демократизм сылтавы белән.

**ФИРМА'Н** *м. полит. истор.*— фәрман, солтан әмере.

**ФИ'РМЕННЫЙ** *торг.*— фирма...-ы; *фирменный бланк* — фирма бланкысы.

**ФИРН** *м. мн.* нет, *геол.*— фирн (бозлыклар башланган урыннарда эре бөртекле тыгыз кар).

**ФИ'РНОВЫЙ** *геол.*— фирн...-ы; *фирновые поля* — фирн кырлары.

**ФИСГАРМО'НИЯ** *ж.*— фисгармония (музыка коралы).

**ФИСК** *м. мн.* нет, *офиц. фин.*— дәүләт казнасы, казна.

**ФИСКА'Л** *м.*— 1. фискал (Пётр I заманында финанс һәм суд органнары өстеннән күзәтеп тору хезмәтен үтәгән кеше); 2. *разг. презрит.* әләкче, чагучы, шымчы.

**ФИСКА'ЛА** *м.* и *ж. разг. презрит.*— к. фискал 2.

**ФИСКА'ЛИТЬ** *несов. презрит.*— әләкләү, чагу.

**ФИСКА'ЛКА** *ж. разг. презрит.*— к. фискала.

**ФИСКА'ЛЬНИЧАТЬ** *несов. простореч. презрит.*— к. фискалить.

**ФИСКА'ЛЬНЫЙ** *офиц. фин.*— казна ...-ы; *фискальные доходы* — казна доходлары.

**ФИСКА'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — 1. *истор.* фискаллык, фискал эше; 2. *разг. презрит.* әләкчелек.

**ФИСТА'ШКА** *ж.*— 1. пестә (чикләвек); 2. пестә агачы.

**ФИСТА'ШКОВЫЙ** — 1. пестә...-ы; *фисташковое дерево* — пестә агачы; 2. пестәле; *фисташковое мороженое* — пестәле мороженый; 3. сыек яшел; *фисташковый цвет* — сыек яшел төс.

**ФИСТА'ШНИК** *м. бот.*— к. фисташка 2.

**ФИСТУЛА'** *ж.*— фистула (1. к. фальцет; 2. *мед.* к. свищ 2; 3. *мед.* эчке органнардагы куышлыктан тәннең тышына чыга торган итеп үткәрелгән ясалма канал, көпшә).

**ФИТИ'ЛЬ** *м.*— филтә, пилтә.

**ФИТИ'ЛЬНЫЙ** — 1. филтәле...; 2. филтә ясый торган.

**ФИТИ'Н** *м. мн.* нет, *апт. мед.*— фитин (тукымаларның туклануын яхшырту өчен кулланыла торган фосфор препараты).

**ФИТИ'НОВЫЙ** *апт. мед.*— фитин...-ы; *фитиновые таблетки* — фитин таблеткалары.

**ФИТЮ'ЛЬКА** *ж. простореч. фам.*— 1. кечкенә нәрсә, әһәмиятсез нәрсә; 2. кечкенә буйлы кеше, ябык кеше.

**ФИ'ША** *ж. устар.*— к. фишка.

**ФИ'ШКА** *ж.*— фишка (төрле уеннарда очколарны, взяткаларны санау өчен сөяктән ясалган шакмаклар).

**ФЛАГ** *м.*— флаг; *государственный флаг Советского Союза* — Советлар Союзының дәүләт флагы. ◇ **Под флагом** *чего перен.*— сылтавы белән, төп максатларны яшереп, ...дигән булып; *под флагом защиты отечества* — ватанны саклау сылтавы белән, ватанны саклыйбыз дигән булып. **Остаться за флагом** *перен.*— артта калу, максатка ирешә алмый калу.

**ФЛАГ-КАПИТА'Н** *м. мор. воен.*— флаг-капитан (флагман штабының начальнигы).

**ФЛА'ГМАН** *м. мор. воен.*— флагман (1. эскадра начальнигы, эскадра командующие; 2. зур хәрби берләшмә командующие урнашкан иң зур корабль яки самолет).

**ФЛА'ГМАНСКИЙ** *воен. мор.*— флагман...-ы; *флагманский корабль* — флагман корабле.

**ФЛАГ-ОФИЦЕ'Р** *м. мор.*— флаг-офицер (флагман штабы адъютанты).

**ФЛАГШТО'К** *м.*— флагшток (флаг күтәрә торган колга).

**ФЛАЖНО'Й** и **ФЛА'ЖНЫЙ**—1. флаг...-ы; *флажный шест* — флаг колгасы; 2. флаг ясый торган; *флажная ткань* — флаг ясый торган тукыма.

**ФЛАКО'Н** *м.*— флакон (кечкенә шешә).

**ФЛАМА'НДКА** *ж.*—фламанд хатын-кызы.

**ФЛАМА'НДСКИЙ** — фламанд...-ы; *фламандский язык* — фламанд теле.

**ФЛАМА'НДЦЫ** *мн.*— фламандлар (төньяк һәм көнбатыш Бельгиядә, шулай ук Франциянең Фландрия өлкәсендә яшәүче халык).

**ФЛАМИ'НГО** *м. нескл.*— фламинго (алсу йонлы, озын муенлы һәм озын аяклы су кошы).

**ФЛАНГ** *м. воен.*— фланг (фронтның, шеренганың уң яки сул очы).

**ФЛАНГО'ВЫЙ** *воен.*— 1. фланг...-ы; фланг ягыннан..., флангтан...; *фланговый огонь* — флангтан ачылган ут; 2. *в знач. сущ.* флангтагы; *правый фланговый* — уң флангтагы.

**ФЛАНЕ'ЛЕВЫЙ** — фланель...,фланельдан тегелгән; *фланелевая юбка* — фланельдән тегелгән юбка, фланель юбка.

**ФЛАНЕЛЕ'Т** *м.*— фланелет (фланельгә охшашлы киже-мамык тукыма).

**ФЛАНЕЛЕ'ТОВЫЙ** — фланелет..., фланелеттан тегелгән.

**ФЛАНЕ'ЛЬ** *ж. мн.* нет — фланель (йомшак мамык тукыма).

**ФЛАНЕ'ЛЬНЫЙ** — фланель...-ы; *фланельный цех* — фланель цехы.

**ФЛАНЁР** *м. пренебр. устар.* — тырай тибеп йөрүче.

**ФЛАНИ'РОВАТЬ** *несов. пренебр. устар.* — эшсез йөрү, тырай тибеп йөрү.

**ФЛАНКИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. воен.* — 1. флангтан дошманга ут ачу; 2. *устар.* флангларны саклау.

**ФЛЕБИ'Т** *м. мед.* — флебит (кан тамырларының ялкынсынуы).

**ФЛЕ'ГМА** *ж. мн.* нет — 1. *мед. устар.* какырык; 2. *книж.* үтә салкын канлылык, сүлпәнлек; 3. *перен. разг.* сүлпән кеше, флегматик; 4. *хим.* флегма (кайнатып куганнан соң савытта куерып калган сыекча).

**ФЛЕГМАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — флегматизм (артык салкын канлылык, сүлпәнлек; дәртсезлек, сүрәнлек).

**ФЛЕГМА'ТИК** *м. книж.* — флегматик (бик салкын канлы кеше, сүлпән кеше).

**ФЛЕГМАТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. к. флегматичный; 2. флегматикларга хас.

**ФЛЕГМАТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — сүлпән, салкын канлы; *флегматичный человек* — сүлпән кеше, салкын канлы кеше.

**ФЛЕГМО'НА** *ж. мед.* — флегмона (клетчатканың эренләп ялкынсынуы).

**ФЛЕ'ЙТА** *ж.* — флейта (музыка коралы).

**ФЛЕЙТИ'СТ** *м.*, **ФЛЕЙТИ'СТКА** *ж.* — флейтист, флейтада уйнаучы.

**ФЛЕ'ЙТНЫЙ** и **ФЛЕ'ЙТОВЫЙ** — флейта...-ы; *флейтовый звук* — флейта тавышы.

**ФЛЕЙЦ** *м.* — флейц (рәссамнар һәм буяучылар куллана торган киң йомшак пумала).

**ФЛЕКСИ'ВНЫЙ** *лингв.* — к. флективный.

**ФЛЕ'КСИЯ** *ж. лингв.* — флексия (1. кушымчаларны үзгәреп сүз формалары ясалу ысулы; 2. сүзне төрләндергәндә аның үзгәрә торган кушымчасы).

**ФЛЕКТИ'ВНЫЙ** *лингв.* — флектив (флексия ярдәмендә яңа сүз һәм грамматик формалар ясый торган); *флективные языки* — флектив телләр.

**ФЛЁР** *м.* — флёр (1. үтә күренмәле юка материя; 2. *перен. книж.* берәр нәрсәне каплап тора торган серле пәрдә).

**ФЛЁРДОРА'НЖ** *м. устар.* — флёрдоранж (киленнең туйда кия торган баш киемендәге чәчәкләр).

**ФЛЁРОВЫЙ** — флёр...-ы; флёрдан ясалган; *флёровый покров* — флёрдан ясалган япма.

**ФЛЕШЬ** *ж. воен. истор.* — флешь (җәенке почмак формасында эшләнгән хәрби ныгытма).

**ФЛИБУСТЬЕ'Р** *м. истор.* — флибустьер (диңгез юлбасары, пират).

**ФЛИБУСТЬЕ'РСКИЙ** — флибустьерлар...-ы; *флибустьерская организация* — флибустьерлар оешмасы.

**ФЛИ'ГЕЛЬ** *м.* — флигель (өйгә тоташтырып салынган бина, яки ишек алдындагы аерым кечкенә йорт).

**ФЛИ'ГЕЛЬ-АДЪЮТА'НТ** *м. дореволь.* — флигель-адъютант (патша свитасына билгеләнгән офицер).

**ФЛИГЕЛЬМА'Н** *м. воен. истор.* — флангтагы солдат.

**ФЛИНТГЛА'С** *м. мн.* нет — флинтглас (оптик пыяланың яхшы сорты).

**ФЛИРТ** *м. мн.* нет — флирт (мәхәббәт сатышу, яратышкан булып кылану).

**ФЛИРТОВА'ТЬ** *несов.* — мәхәббәт сату.

**ФЛОКС** *м.* — флокс (декоратив үсемлек).

**ФЛО'РА** *ж. мн.* нет, *книж.* — флора (билгеле бер өлкәгә яки геологик эпохага хас булган үсемлекләр дөньясы).

**ФЛОРА'НС** *м. мн.* нет, *спец.* — флоранс (кием эчлегенә китә торган юка ефәк тукыма).

**ФЛОРИ'Н** *м.* — флорин (1. *истор.* борынгы Италиядә алтын акча; 2. Голландиядә акча берәмлеге).

**ФЛОРИ'СТ** *м. науч.* — флора белгече, үсемлекләр белгече, ботаник.

**ФЛОТ** *м.* — флот (1. бер илнең яки бер оешманың сәүдә һәм хәрби судноларының барысы бергә; *военно-морской флот* — хәрби диңгез флоты; *торговый флот* — сәүдә флоты; 2. теге яки бу диңгездә йөри торган барлык судноолар; 3. к. флотилия. ◇ **Воздушный флот** — һава флоты (бер илнең барлык авиациясе һәм очу аппаратлары).

**ФЛОТА'ТОР** и **ФЛОТА'ТОРЩИК** *м. спец.* — флотация белгече.

**ФЛОТАЦИО'ННЫЙ** *горн.* — флотация...-ы; *флотационная машина* — флотация машинасы.

**ФЛОТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *горн.* — флотация (руданы баету ысулларының берсе).

**ФЛОТИ'ЛИЯ** *ж. мор.* — флотилия (1. берәр елгада, күлдә йөри торган судноларның барысы; *Каспийская флотилия* — Каспий флотилиясе; 2. судноолар отряды; *подводная флотилия* — су асты флотилиясе; *китобойная флотилия* — кит аулау флотилиясе).

**ФЛОТОВО'ДЕЦ** *м. книж.* — флот башлыгы; *русские флотоводцы* — рус флот башлыклары.

**ФЛО'ТСКИЙ** — 1. флотта хезмәт итүчеләр...-ы; флот...-ы; *флотские нравы* — флот гадәтләре; 2. *в знач. сущ. разг.* — матрос; флотта хезмәт итүче.

**ФЛУКТУА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *науч.* — к. колебаться 1, 4.

**ФЛУКТУИ'РОВАТЬ** *несов. науч.* — тирбәлеп тору, үзгәреп тору.

**ФЛУОРЕСЦЕ'НЦИЯ** *ж. мн.* нет, *физ.* — флуоресценция (яктырту тәэсирендә кайбер җисемнәрнең нур чәчүе, ялтыравы, мәсәлән, кояш нурлары белән яктыртылганда керосинның зәңгәрсу төскә керүе).

**ФЛОРЕСЦИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — яктылык тәэсирендә ялтырау, нур чәчү.

**ФЛЮГА'РКА** *ж.*— 1. флюгарка (а. спец. к. флюгер 1; б. *мор.* кайсы судноныкы икәнлеген билгеләү өчен көймәгә куелган флаг; в *спец.* җил вакытында төтенне морҗадан тоткарсыз чыгару өчен аның өстенә куелган җайланма); 2. *перен. простореч. пренебр.* к. флюгер 2.

**ФЛЮ'ГЕР** *м.*— 1. флюгер (а. җилнең юнәлешен күрсәтә торган прибор; б. *воен.* сөңгедәге кечкенә флаг); 2. *перен. разг. пренебр.* аумакай (фикере, карашы тиз үзгәрүчән кеше).

**ФЛЮ'ГЕРНЫЙ** — 1. флюгер...-ы; 2. *перен. разг. пренебр.* аумакай, карашы тиз үзгәрүчән.

**ФЛЮИ'Д** *м. книж.*— флюид (спиритлар карашынча, кешенең тәненнән чыга торган психик ток).

**ФЛЮКТУА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — к. флуктуация.

**ФЛЮОРЕСЦЕ'НЦИЯ** — к. флуоресценция.

**ФЛЮС** *м.*— флюс (теш авырту сәбәпле янак шешү авыруы).

**ФЛЯ'ГА** *ж.*— фляга (1. берәр материя белән тышланган һәм иңбаш аша тагып йөртелә торган юл шешәсе; 2. сыекчалар сала торган зур савыт).

**ФЛЯ'ЖКА** *ж.*— к. фляга 1.

**ФЛЯ'ЖНЫЙ** — фляга...-ы; *фляжная пробка* — фляга бөкесе.

**ФОБИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.*— фобия (сәбәпсез курку авыруы, психик авыру).

**ФОЙЕ'** *ср. нескл.*— фойе (театрларда антракт вакытында тамашачылар йөреп ял итә торган урын).

**ФОК** *м.*— фок (суднода алгы мачтаның аскы җилкәне).

**ФОКА'ЛЬНЫЙ** — к. фокусный.

**ФОК-МА'ЧТА** *ж. мор.*— фок-мачта, алгы мачта (суднода).

**ФОКСТЕРЬЕ'Р** *м.*— фокстерьер (кечкенә ау эте).

**ФОКСТРО'Т** *м.*— фокстрот (бию төре, бию көе).

**ФОКСТРО'ТНЫЙ** — фокстрот...-ы; *фокстротный мотив* — фокстрот көе.

**ФО'КУС** I *м.*— 1. фокус (а. *физ.* сферик көзгедән кайтарылган яки линза аша үткән нурларның кисешкән ноктасы; б. рәсемгә төшерелә торган әйбернең фотоаппаратта иң яхшы күренә торган ноктасы; в. *мед.* организмда ялкынсыну процессының төп учагы); 2. *перен. книж.* үзәк, урта (берәр нәрсәнең тупланган урыны); *в фокусе событий* — вакыйгаларның үзәгендә.

**ФО'КУС** II *м.*— 1. фокус (хәйлә һәм осталык белән башкарылган шаккатыргыч эш); 2. *перен. разг. фам. неодобр.* хәйләле эш; 3. *перен. разг. фам. неодобр.* каприз, көйсезлек, киреләнү, холыксызлык, кыланыш; *брось свои фокусы* — ташла әле шул кыланышларыңны.

**ФО'КУСНИК** *м.*, **ФО'КУСНИЦА** *ж.*— 1. фокусчы, фокус күрсәтүче; 2. *перен. разг. фам. неодобр.* холыксыз кеше, көйсез кеше, кыланчык кеше.

**ФО'КУСНИЧАТЬ** *несов. разг.*— 1. *редко* фокуслар күрсәтү; 2. *перен. фам. неодобр.* капризлану, көйсезләнү, холыксызлану, киреләнү; 3. *фам. неодобр.* алдау, хәйләләү, икейөзлеләнү.

**ФО'КУСНЫЙ** *спец.*— фокус...-ы; *фокусное расстояние* — фокус ераклыгы.

**ФО'КУС-ПОКУС** *м.*— к. фокус II.

**ФОЛ** *м. спорт*— фол (тупас алым кулланып уен кагыйдәсен бозу).

**ФОЛИА'НТ** *м. книж.*— фолиант (зур форматлы калын китап).

**ФО'ЛИО** — фолио (1. *тип.* к. ин-фолио; 2. *нескл. ср. бухг.* исәп-хисап кенәгәсенең бер үк тәртип номеры куелган сул һәм уң битләре).

**ФОЛЛИ'КУЛ** *м. анат.*— фолликул, куыкчык (мәсәлән, лимфа бизләре куыкчыгы).

**ФОЛЛИКУЛЯ'РНЫЙ** *анат. мед.*— фолликуляр...-ы; *фолликулярная ангина* — фолликуляр ангина.

**ФОЛЬВА'РК** *м. обл.*— кечкенә усадьба, кечкенә утар.

**ФО'ЛЬГА** *ж. мн.* нет — фольга (көзге ясау эшендә, китап төпләгәндә һ. б. кулланыла торган бик юка металл кәгазь).

**ФОЛЬГОВЩИ'К** *м. спец.*— фольгачы (фольга ясаучы мастер яки фольга куллана торган производство эшчесе).

**ФО'ЛЬГОВЫЙ** — фольгадан ясалган.

**ФО'ЛЬКЕТИНГ** *м.*— фолькетинг (Дания парламентында түбәнге палата).

**ФОЛЬКЛО'Р** *м. мн.* нет, *книж.*— фольклор (1. халык авыз иҗаты; 2. гомумән халыкларның гореф-гадәтләре, җырлары, әкиятләре һәм көнкүрештә була торган башка күренешләр; 3. к. фольклористика).

**ФОЛЬКЛОРИ'СТ** *м. спец.*— фольклорист, фольклорчы, фольклор белгече.

**ФОЛЬКЛОРИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *науч.*— фольклористика (фольклор турындагы фән).

**ФОЛЬКЛОРИСТИ'ЧЕСКИЙ** — фольклористик, фольклор өлкәсендә алып барыла торган; *фольклористические исследования* — фольклористик тикшеренүләр.

**ФОН** I *м.*— 1. фон (а. рәсемдә, картинада — нигез буяу, җирлек буявы; б. рәсемнең, картинаның арткы планы, күренеше); 2. *перен. книж.* шартлар, гомуми шартлар, торыш; *на фоне текущих международных событий* — агымдагы халыкара вакыйгалар шартларында.

**ФОН** II *разг. устар.*— 1. *разг.* немец; 2. һавалы кеше, тәкәббер кеше, үзен әллә кемгә куючы кеше. ◇ **Фон-барон** *разг. шутл.*— к. фон II, 2.

**ФОН** III *м. спец.*— шытырдаган тавыш (мәсәлән, телефон трубкасында, репродукторда).

**ФОНА'РНЫЙ** — фонарь...-ы; *фонарный столб* — фонарь баганасы.

**ФОНА'РЩИК** *м.*, **ФОНА'РЩИЦА** *ж. спец* — фонарь кабызучы, фонарьчы.

**ФОНА'РЬ** *м.*— фонарь (1. яктырту приборы; *уличный фонарь* — урам фонаре; 2. *архит.* яктылык төшсен өчен өй түбәсенә ясалган тәрәзә; 3. *тип.* басма текстның

зур бер өлеше башланып киткәндә, мәсәлән, бүлек башында куела торган зур хәреф; 4. *разг. шутл.* бәреп яки сугып күгәрткән җир).

**ФОНАЦИО'ННЫЙ** *лингв.*— фонацион...; *фонационный аппарат* — фонацион аппарат.

**ФОНА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — фонация (авазларны әйтү процессы).

**ФОНД** *м.*— фонд (1. аерым бер максат өчен билгеләнгән акча яки әйбер; *фонд заработной платы* — эш хакы фонды; *неделимый фонд колхоза* — колхозның бүленми торган фонды; 2. берәр нәрсәнең ресурсы, запасы; *семенной фонд колхоза* — колхозның орлык фонды; *основной словарный фонд языка* — телнең төп сүзлек фонды; 3. *только мн. фин.* процентлы, кыйммәтле кәгазьләр). ◇ **Золотой фонд** — алтын фонды (1. алтын акча запасы; 2. *перен.* берәр нәрсәнең иң яхшы, иң кыйммәтле өлеше, алтын фонды; *передовики производства —золотой фонд промышленности* — производствоның алдынгы эшчеләре — промышленностьның алтын фонды).

**ФО'НДОВЫЙ** — фонд...-ы; *фондовый капитал* — фонд капиталы; *фондовые операции* — фонд операцияләре; *фондовая биржа* — фонд биржасы (эре сәүдә эшләре алып бара торган учреждение).

**ФОНЕ'МА** *ж. лингв.*— фонема (1. *лингв.* сүзләрнең мәгънәләрен һәм аларның грамматик кисәкләрен аеруга сәләтле булган сөйләм авазы; 2. *мед.* юк сүзләрне ишетү авыруы).

**ФОНЕМАТИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.* — фонематик; фонемалар...-ы; *фонематический состав языка* — телнең фонематик составы.

**ФОНЕ'ТИКА** *ж. лингв.*— фонетика (1. тел белемендә телнең аваз төзелешен өйрәнә торган бүлек; 2. телнең авазлар составы).

**ФОНЕТИ'СТ** *м. лингв.*— фонетист (фонетика белгече).

**ФОНЕТИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.*— фонетик; *фонетическое исследование* — фонетик тикшеренү; *фонетическая транскрипция* — фонетик транскрипция (сүзләрне нәкъ ишетелгәнчә, әйтелгәнчә язу).

**ФОНИ'ЗМ** *м. псих.*— фонизм (күрү нәтиҗәсендә яки башка тәэсирләр аркасында колакка тавыш ишетелү).

**ФО'НИКА** *ж. мн.* нет, *лингв.*— фоника (телнең авазлар составы).

**ФОНИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.*— фоник; *фонические явления* — фоник күренешләр.

**ФО'НОВЫЙ** — 1. фон...-ы, фондагы; *фоновый цвет* — фон төсе; 2. бер генә төсле; *фоновые обои* — бер генә төсле обойлар.

**ФОНОГРА'ММА** *ж. спец.* — фонограмма (фонограф ярдәмендә валикка, плёнкага, пластинкага алынган авазлар язмасы).

**ФОНО'ГРАФ** *м. спец.* — фонограф (авазларны язып ала торган прибор).

**ФОНОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — фонографик; *фонографическая запись* — фонографик язу.

**ФОНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.* — фонологик; *фонологический метод* — фонологик метод.

**ФОНОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *лингв.* — фонология (тел белемендә фонемалар системасын һәм аларның үзгәрешен өйрәнә торган бүлек).

**ФОНО'МЕТР** *м. физ.* — фонометр (тавышның, авазның көчен үлчи торган прибор).

**ФОНОМЕТРИ'ЧЕСКИЙ** *физ.* — фонометрик; *фонометрические исследования* — фонометрик тикшеренүләр.

**ФОНОСКО'П** *м.* — фоноскоп (1. *мед.* йөрәк һәм үпкәне тыңлау приборы; 2. *лингв.* авазларның үзенчәлекләрен, аларны әйткәндә ирен һәм йөз мускулларының хәрәкәтләрен өйрәнү өчен эшләнгән прибор).

**ФОНТА'Н** *м.* — фонтан (көчле рәвештә югарыга атылып чыга торган су яки башка берәр сыек әйбер); *нефтяной фонтан* — нефть фонтаны; *бить фонтаном* — фонтан булып атылып чыгу. ◇ **Фонтан слёз** — күз яше дәрьясы, чиксез, чамасыз күп күз яше. **Фонтан красноречия** *перен. книж.* — сүз ташкыны.

**ФОНТАНИ'РОВАТЬ** *несов. тех.* — атылып бәреп чыгу, фонтан булып атылып чыгу; *нефть фонтанирует* — нефть фонтан булып атылып чыга.

**ФОНТА'ННЫЙ** — фонтан ...-ы; *фонтанная вода* — фонтан суы.

**ФО'РА** I *ж. спорт. разг.* — фора (берәр уенда катнашучыларның көчләренә тарафыннан көчсезрәгенә ясалган ташлама, льгота).

**ФО'РА** II *в знач. пов. накл. устар.* — к. бис.

**ФО'РВАРД** *м. спорт.* — форвард (футбол яки хоккей командасында һөҗүм итүче уенчы).

**ФОРДЕВИ'НД** *м. мн.* нет, *мор.* — фордевинд (1. судноның барышы уңаена искән җил; 2. судноның җил уңаена барышы).

**ФОРДИ'ЗМ** *м. мн.* нет — фордизм (капиталистик илләрдә производствоны оештыруда эксплуатацияне көчәйтүгә нигезләнгән ысул).

**ФОРДЫБА'ЧИТЬ, ФОРДЫБА'ЧИТЬСЯ** *несов. простореч.* — киреләнү, тупас рәвештә каршы килү, тупас кылану, эреләнеп дорфа кылану (сүздә, мөгамәләдә).

**ФОРЕ'ЙТОР** *м. устар.* — форейтор (мичәүләп җигелгән атларның очтагысына атланып баручы кучер).

**ФОРЕ'ЙТОРСКИЙ** *устар.* — форейтор ...-ы; *форейторское седло* —форейтор ияре.

**ФОРЕ'ЛЕВЫЙ** — форель ..., ала балык ...; *форелевые ловли* — форель тоту, ала балык аулау.

**ФОРЕ'ЛЬ** *ж.* — форель, ала балык.

**ФОРЕ'ЛЬНЫЙ** — форель ...-ы; ала балык ...-ы; *форельный вкус* — ала балык тәме.

**ФО'РЗАЦ** *м.* — форзац (икегә бөкләнеп яртысы китап тышының эчке ягына ябыштырылган, икенче яртысы буш калган бит).

**ФО'РМА** *ж.* — 1. форма, тышкы күренеш; *иметь форму шара* — шар формасында

булу; 2. *только мн.* гәүдә, сын; килеш-килбәт; 3. *спец.* калып, форма; *форма для шляп* — эшләпәләр калыбы; *чугунная форма для отливки* — эреган металларны кою өчен ясалган чуен форма; 4. *офиц. канц.* форма, тәртип; *представить сведения по форме № 1* — беренче номер форма буенча мәгълүматлар бирү; *форма протокола* — протокол формасы; 5. форма (билгеле бер үрнәктәге рәсми кием, мәсәлән, хәрбиләр, укучылар һ. б. киеме); *военная форма* — хәрби форма, хәрби кием; *парадная форма* — парадка киеп чыга торган форма; 6. *перен.* рәсмилек; *это всё — пустая форма* — моның барысы да — коры рәсмилек кенә; *ради формы* — рәсмилек өчен; 7. форма, төзелеш, структура; *форма правления* — идарә итү формасы (мәсәлән, монархия, буржуаз республика һ. б.); 8. *лит. искус.* форма; *форма стиха* — шигырь формасы; *проблема формы и содержания* — эчтәлек һәм форма проблемасы; 9. *лингв.* форма; *форма слова* — сүз формасы; *формы словоизменения* — сүзләрнең төрләнеш формалары; *глагольные формы* — фигыль формалары; 10. *тип.* — форма (типографиядә набор кыстыру өчен тимер рам һәм шул рамга кыстырылган набор үзе).

**ФОРМАЛИ'ЗМ** *м. мн.* нет — формализм (1. *филос.* идеалистик философиядә эчтәлеккә әһәмият бирмичә форманы гына нигез итеп карау, форманы эчтәлектән аеру; 2. *науч.* әдәбиятта, сәнгатьтә эчтәлекне һәм идеялелекне инкарь итеп, фәкать формага гына әһәмият бирә торган идеалистик юнәлеш; 3. *перен.* эштә, хезмәттә формаль якка гына әһәмият бирү, форма саклау, хәрефкә ябышып яту).

**ФОРМАЛИ'Н** *м. мн.* нет — формалин (дезинфекция ясау өчен кулланыла торган матдә).

**ФОРМАЛИ'ННЫЙ** и **ФОРМАЛИ'НОВЫЙ** — формалин ...-ы; *формалинный запах* — формалин исе.

**ФОРМАЛИ'СТ** *м.*, **ФОРМАЛИ'СТКА** *ж.* — формалист (1. формализм тарафдары; 2. коры форма саклауга гына бирелгән кеше).

**ФОРМАЛИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *разг. пренебр.* — коры формализм, эшнең тышкы ягына гына әһәмият бирү.

**ФОРМАЛИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книжн.* — формалистик, формализм белән сугарылган; *формалистическое отношение к делу* — эшкә формалистик мөнәсәбәт.

**ФОРМАЛИ'СТСКИЙ** *книжн.* — формалистларча ..., формалистларга хас; *формалистский подход к литературному произведению* — әдәби әсәргә формалистларча караш.

**ФОРМА'ЛЬНОСТЬ** *ж. только ед.* — формальлек (1. формага гына, тышкы күренешкә генә бирелүчәнлек; 2. берәр эшне башкарганда үтәлергә тиеш булган вак-төяк шартлар).

**ФОРМА'ЛЬНЫЙ** — 1. *науч.* форма ...-ы, форма ягыннан; *формальные особенности слов* — сүзләрнең форма үзенчәлекләре; *формальный анализ стихотворения* — шигырьгә форма ягыннан анализ ясау; 2. формаль, формализмга нигезләнгән; *формальная логика* — формаль логика; *формальный метод в литературоведении* — әдәбият белемендә формаль метод; 3. *офиц. канц.* рәсми, рәсми рәвештә, формаль; *формальный отказ* — рәсми рәвештә баш тарту; 4. формаль; *формальное отношение к делу* — эшкә формаль караш; 5. формаль, форма өчен генә булган, күз буяу өчен генә эшләнгән; *формальное право в капиталистических странах* — капиталистик илләрдә форма өчен генә булган хокук.

**ФОРМА'ЛЬЩИНА** *ж. разг. пренебр.* — к. формалистика.

**ФОРМА'НТ** *м. лингв.* — формант (сүз ясагыч һәм сүз төрләндергеч кушымчаларның гомуми исеме).

**ФОРМА'Т** *м.* — формат (1. китапның, кәгазь табагының, карточканың һ. б. йөззурлыгы; 2. *тип.* набор битенең озынлыгы һәм биеклеге, набор юлының озынлыгы; 3. *спец.* берәр нәрсәнең күчермәсен (копиясен) алу өчен өлге).

**ФОРМАТИ'В** *м. лингв.* — к. формант.

**ФОРМА'ТКА** *ж. спец.* — форматка (билгеле бер форматтагы чертёж кәгазе).

**ФОРМА'ЦИЯ** *ж.* — формация (1. берәр нәрсәнең, мәсәлән, кешелек җәмгыятенең үсешендә мәгълүм бер баскыч, стадия; 2. *перен.* карашлар системасы; *люди новой формации* — яңа формация кешеләре; 3. *геол.* мәгълүм бер геологик дәвердә барлыкка килгән җир катламнары).

**ФО'РМЕНКА** *ж. спец.* — форменка (матрос курткасы).

**ФО'РМЕННЫЙ** — 1. форма буенча эшләнгән; *форменная фуражка* — форма буенча эшләнгән (тегелгән) фуражка; 2. *простореч.* законча эшләнгән; *форменное удостоверение* — законча эшләнгән (язылган) таныклык. ◇ **Форменный скандал** — зур җәнҗал **Форменный дурак** — шыр тиле, тиленең тилесе, ахмакның ахмагы. **Форменный плут** — алдакчының алдакчысы, чеп-чи алдакчы.

**ФОРМИРОВА'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* к. формировать, формироваться; 2. *воен.* яңа төзелгән гаскәри часть.

**ФОРМИРОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *книжн.* формалаштыру, формага кертү; калыпка салу, форма бирү; *формировать произведение* — әсәрне бер калыпка салу; 2. *книжн.* төзү, оештыру; булдыру; *формировать правительство* — хөкүмәт төзү; *формировать воинские части* — хәрби частьлар оештыру; 3. *ж.-д.* төзү, оештыру; *формировать поезд* — поезд төзү (вагоннарны бер-берсенә теркәп поезд төзү).

**ФОРМИРОВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. формалашу; *характер формируется под влиянием окружающей среды* — характер мохит (тирә-юнь) тәэсирендә формалаша; 2. *(развиваться физически)* формалашып килү, формалашып бару; 3. *страд.* формага кертелү, формалаштырылу, форма бирелү; 4. *страд.* төзелү, оештырылу.

**ФОРМИРО'ВКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — к. формирование 1.

**ФОРМИРО'ВОЧНЫЙ** *спец.* — төзү ...-ы, оештыру ...-ы; *формировочный пункт* — оештыру пункты.

**ФОРМОВА'ЛЬНЫЙ** *тех.* — (тиешле) формага кертә торган, (кирәкле) форма бирә торган; *формовальный круг* — формага кертә торган түгәрәк (балчыктан әйберләр ясаганда аларга тиешле форма бирә торган станок).

**ФОРМОВА'ТЬ** *несов. тех.* — **1.** *книж.* к. формировать 1; **2.** *тех.* (тиешле) формага кертү, (кирәкле) форма бирү; **3.** *тех.* форма (калып) әзерләү.

**ФОРМОВА'ТЬСЯ** *несов.* — **1.** (тиешле) формага керү, (тиешле) форма алу; **2.** *страд.* — формага кертелү, форма бирелү.

**ФОРМО'ВКА** *ж.* — **1.** *только ед. (действие)* к. формовать; **2.** *тех.* форма, калып.

**ФОРМОВО'Й** — **1.** *тех.* форма (калып) ясау өчен яраклы; *формовая глина* — форма ясау өчен яраклы балчык; **2.** формалы, формага салып ...-ган; *формовой хлеб* — формага салып пешерелгән икмәк.

**ФОРМО'ВОЧНЫЙ** — **1.** к. формовой 1; **2.** (билгеле бер) калыпка салу ...-ы; формага салу ...-ы; *формовочная машина* — калыпка салу машинасы.

**ФОРМО'ВЩИК** *м. спец.* — формовщик, формалар (калыплар) ясаучы.

**ФОРМООБРАЗОВА'НИЕ** *ср. науч.* — **1.** *только ед.* формалашу; **2.** билгеле бер форма алган нәрсә, формалашкан нәрсә.

**ФОРМООБРАЗОВА'ТЕЛЬНЫЙ** — формалашу ...-ы; *формообразовательный процесс* — формалашу процессы.

**ФО'РМУЛА** *ж.* — формула (**1.** берәр фикер яки кагыйдәнең кыска һәм анык тәгъбире, билгеләмәсе; **2.** *мат.* шартлы билгеләр белән күрсәтелгән математик мөнәсәбәтләр; *алгебраическая формула* — алгебраик формула; **3.** *хим.* катлаулы матдәләр составының һәм химик процессларның хәрефләр белән шартлы рәвештә билгеләнүе.

**ФОРМУЛИ'РОВАТЬ** *сов. книж.* — кыска һәм ачык итеп әйтеп бирү, тәгъбирләү; *формулировать свою мысль* — үз фикереңне кыска һәм ачык итеп әйтеп бирү.

**ФОРМУЛИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — кыска һәм ачык итеп әйтеп бирелү, тәгъбирләнү.

**ФОРМУЛИРО'ВКА** *ж. книж.* — **1.** *только ед.* к. формулировать; **2.** (кыска һәм ачык итеп) әйтелгән фикер.

**ХОЛУ'Й** *м. презрит.* — **1.** *доревол.* холуй, лакей; **2.** *перен. простореч.* ялагай, тәлинкә тотучы.

**ХОЛУ'ЙСКИЙ** *презрит.* — лакейлар...-ы; холуйлар...-ы; тәлинкә тотучылар...-ы; *холуйские привычки* — тәлинкә тотучылар гадәте.

**ХОЛУ'ЙСТВО** *ср. презрит.* — **1.** *собир. дореволю.* лакейлар, холуйлар; **2.** *простореч.* ялагайлык, тәлинкә тоту.

**ХОЛУ'ЙСТВОВАТЬ** *несов. простореч. презрит.* — ялагайлану, тәлинкә тоту, холуйларча (лакейларча) кылану.

**ХОЛЩЕ'ВНИК** *м. обл. устар.* — к. холстяник.

**ХОЛЩО'ВЫЙ** — киндер..., киндердән тегелгән; *холщовый мешок* — киндердән тегелгән капчык; *холщовая рубашка* — киндер күлмәк.

**ХО'ЛЯ** *ж. мн.* нет — тәрбия, кайгырту, иркәләү.

**ХОЛЯ'ВА** *ж.* — **1.** холява (пыяла производствосында табаклы пыяла ясау өчен өреп цилиндр рәвешенә китерелгән пыяла); **2.** *обл.* итек кунычы; **3.** *обл. спец.* кин кыска шланг.

**ХОМУ'Т** *м.* — **1.** камыт; **2.** *перен.* камыт, авырлык, мәшәкать, имгәк; **3.** *тех.* беркетмә, атлама, каптыргыч.

**ХОМУТА'ТЬ** *несов. спец.* — камытлау, камыт кигезү.

**ХОМУТА'ТЬСЯ** *несов. спец.* — камытлану, камыт кидерелү.

**ХОМУ'ТИК** *м.* — **1.** кечкенә камыт; **2.** хомутик (а. *тех.* кыскыч, кыстыргыч, зажим, кыру станогында эшкәртелә торган әйберне кыстырып кую өчен кулланма; б. *воен.* мылтыкта һәм пулемётта прицелның бер кисәге).

**ХОМУТИ'НА** *ж.* — бөят, камыт бөяте.

**ХОМУ'ТНИК** *м.* — камыт ясаучы, камытчы.

**ХОМУ'ТНЫЙ** — камыт ...-ы; *хомутные гвозди* — камыт кадаклары.

**ХОМУ'ТЧИК** — к. хомутник.

**ХОМЯ'К** *м.* — әрлән (җәнлек).

**ХОМЯ'ЧИЙ** — әрлән...-ы; *хомячья шкура* — әрлән тиресе.

**ХОНДРИ'ЛЛА** *ж. бот.* — хондрилла (каучук бирә торган үсемлек).

**ХОП** *междом.* — к. гоп.

**ХО'ППЕР** *м.* — хоппер (йөкне үзе бушата торган вагон).

**ХОР** *м.* — хор (**1.** *истор.* борынгы грек драмасында җыр һәм бию белән чыгыш ясаучы бер төркем; **2.** *поэт.* һәрвакыт бергә була торган төркем; **3.** җырны бергә башкаручылар төркеме; *хор оперного театра* —

опера театрының хоры; 4. *устар.* оркестр; 5. күп тавыш белән башкарыла торган музыкаль әсәр). ◇ **Говорить хором** — барысы берьюлы сөйләү.

**ХОРА'Л** *м.*— хорал (1. *церк.* католикларда һәм протестантларда дини җырлар җырлау; 2. *муз.* шул формада язылган музыкаль әсәр).

**ХОРВА'ТКА** *ж.*— хорват хатын-кызы.

**ХОРВА'ТСКИЙ** — хорватлар ...-ы; хорват ...-ы; *хорватский язык*—хорват теле.

**ХОРВА'ТЫ** *м.* (*ед.* хорват) — хорватлар (Югославия составына кергән Хорватиянең төп халкы).

**ХО'РДА** *ж.* — хорда (1. *мат.* кәкре сызыкның ике ноктасын тоташтыручы туры сызык; 2. *биол.* арка сөяге, мәсәлән, балыкларда).

**ХОРДО'МЕТР** *м. муз.*—хордометр (музыкаль инструментларның кылларының калынлыгын үлчи торган прибор).

**ХОРЁВЫЙ** — көзән...-ы; *хорёвая нора* — көзән өне.

**ХОРЕИ'ЧЕСКИЙ** *лит.*— хорей...-ы; хорей белән язылган; *хореические стихи* — хорей белән язылган шигырьләр.

**ХОРЕ'Й** I *м.*— хорей (басымы беренче иҗеккә төшә торган ике иҗекле шигъри буын).

**ХОРЕ'Й** II *м. обл.*—колга (чанага җигелгән боланнарны куу өчен агач колга).

**ХОРЁК** *м.*— көзән, сасы көзән.

**ХОРЕОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — хореографик, хореография...-ы; *хореографическое искусство*—хореографик сәнгать.

**ХОРЕОГРА'ФИЯ** *ж.* — хореография (1. бию сәнгате; 2. балет әсәрләрен сәхнәгә кую).

**ХОРИ'СТ** *м.*—хорчы, хор артисты.

**ХОРИ'СТКА** *ж.*—хорчы, хор артисткасы.

**ХОРИЯ'МБ** *м.*—хориямб (хорей һәм ямбтан гыйбарәт булган дүрт иҗекле шигъри буын).

**ХОРМЕ'ЙСТЕР** *м. театр.*— хормейстер (1. операда хор җитәкчесе; 2. хорда дирижёр ярдәмчесе).

**ХОРМЕ'ЙСТЕРСКИЙ** *театр.*— хормейстер...-ы; хормейстерлык...-ы; *хормейстерская должность* — хормейстр вазифасы.

**ХОРО'БРЫЙ** *нар. поэт.*— к. храбрый.

**ХОРОВО'Д** *м.*—хоровод, әйлән-бәйлән уены (түгәрәккә тезелеп әйләнеп-йөреп күмәкләшеп җырлау һәм бию уены).

**ХОРОВО'ДИТЬСЯ** *несов.*— әвәрә булу; буталып йөрү, әвәрә килү (берәр кеше белән).

**ХОРОВО'ДНИК** *м.*, **ХОРОВО'ДНИЦА** *ж.*—1. *обл.* (әйлән-бәйлән уенында) башлап җырлаучы; 2. *просторечь.* әвәрә булып йөрүче, әвәрә килеп йөрүче (берәр кеше белән).

**ХОРОВО'ДНЫЙ**— әйлән-бәйлән ...-ы; әйлән-бәйлән уены...-ы; *хороводные песни* — әйлән-бәйлән җырлары.

**ХОРОВО'Й** — 1. хор белән..., хор белән үтәлә торган; *хоровое пение* — хор белән җырлау; 2. хор...-ы; *хоровой кружок*—хор түгәрәге.

**ХОРО'МИНА** *ж. обл. шутл.*—зур өй, зур йорт.

**ХОРО'МЫ** *ед.* нет— 1. *обл., с тарин.* зур агач өй; 2. *устар., теперь ирон., шутл.* күп бүлмәле йорт.

**ХОРОНИ'ТЬ** *несов.*— 1. күмү, җирләү; 2. *перен.* оныту, искергән дип исәпләү; *хоронить старые обычаи*—иске гадәтләрне оныту; 3. *простореч. старин.* яшерү. ◇ **Хоронить концы**—к. конец.

**ХОРОНИ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. *простореч*-яшеренү, качу; 2. *страд.* күмелү; 3. *страд*-яшерелү; 4. *страд.* онытылу, искергән дип саналу.

**ХОРОХО'РИТЬСЯ** *несов. разг. фам.*— әтәчләнү, һаваланy, һавалы тоту, гайрәт чәчү.

**ХОРОШЕ'НЕЧКО** *нареч. разг. фам.*— яхшы гына, яхшылап кына; *подумай хорошенечко*—яхшылап кына уйлап кара.

**ХОРО'ШЕНЬКИЙ** *разг.*—1. к. хороший 1, 2, 3; 2. чибәр генә, сылу гына; *хорошенькое личико*—чибәр генә йөз. ◇ **Хорошенького понемножку** *разг. ирон.*— яхшы нәрсә күп булмый; майлы ботка күп булмый.

**ХОРОШЕ'НЬКО** *нареч. разг.*— яхшылап, әйбәтләп, яхшы гына; *я и сам не знаю хорошенько*— мин үзем дә яхшылап белмим.

**ХОРОШЕ'ТЬ** *несов.*—1. матурлану, чибәрләнү; 2. яхшылану, яхшыру, яхшыра бару; *наши города хорошеют с каждым днём*—безнең шәһәрләр көннән-көн яхшыралар.

**ХОРО'ШЕЕ** *в знач. сущ. ср. мн.* нет — яхшылык, яхшы нәрсә; *что уж там будет? не жду я хорош го* (Некрасов) — нәрсә булыр инде анда? яхшылык көтмим; *ничего хорошего тут нет*—монда бернинди яхшылык та юк. ◇ **Желаю вам всего хорошего**—сезгә яхшы теләктә калам.

**ХОРО'ШИЙ**—1. яхшы, әйбәт; *хороший человек* — яхшы кеше; 2. *разг. только кратк. форма* яхшы, шәп; *хорош, нечего сказать*—яхшы, әйтеп торасы да юк (көлеп, мыскыл итеп әйткәндә); 3. хөрмәткә лаеклы, әдәпле, яхшы; *с ним хорошее общ-ство дружно*—аның белән хөрмәткә лаеклы кешеләр дус; 4. шактый зур, яхшы гына; *съесть хорошую порцию мороженого*— шактый зур порция мороженое ашап бетерү; 5. якын, яхшы, ихлас күңелле; *он мой хороший друг*—ул минем яхшы дустым; 6. матур, чибәр, күркәм, сокландыргыч; *эта женщина была замечательно хороша собой* (Лесков) — бу хатын искиткеч матур иде. ◇ **Жить по хорошему** — тату тору.

**ХОРОШО'**—1. *нареч.* яхшы, әйбәт; *хорошо работает* — яхшы эшли; *хорошо вести себя* — үзен яхшы тоту; 2. *безл., в знач. сказ.* яхшы; *мне здесь хорошо*—миңа монда яхшы; *хорошо, что он придёт сегодня* — әгәр ул бүген килсә яхшы (булыр иде); 3. (*утвердительная частица* яхшы, ярый; *хорошо, я этого не забуду* — ярый, мин моны онытмам.

**ХОРТ** *м. охот.*— бурзай эт.

**ХОРУ'ГВЬ** *ж.*— хоругвь (1. *истор.* гаскәр байрагы; 2. *церк.* Гайсә рәсеме төшерелгән байрак).

**ХОРУ'НЖИЙ** *м. воен.*—хорунжий (1. революциягә кадәр казачий гаскәрдә офицер чины; 2. *старин.* байрак йөртүче).

**ХО'РЫ** *ед.* нет — балкон (театр залларында).

**ХОРЬ** *м.*— к. хорёк.

**ХОРЬКО'ВЫЙ** — көзән...-ы; көзән тиресеннән тегелгән; *хорьковая шуба* — көзән тиресеннән тегелгән тун.

**ХОТЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — теләк, теләү.

**ХОТЕ'ТЬ** *несов.*—**1.** теләү, ...-сы килү; *хотеть пить* — эчәсе килү; *я хотел написать статью* — мин мәкалә язарга теләгән идем; *мы хотим мира* — без тынычлык телибез; 2. көтү; *хотел от него правды* — аңардан хакыйкать көткән идем. ◇ **Если хотите** или **если хочешь** — беләсегез килсә; *если хотите, в этом случае он прав* — беләсегез килсә, бу очракта ул хаклы. **Как хотите** или **как хочешь** — теләсәң нишлә, теләсәгез нишләгез; *как хотите, но это неверно* — теләсәгез нишләгез, ләкин бу дөрес түгел. **Кому хочешь** — теләсәң кемгә; *отдай кому хочешь* — теләсәң кемгә бир. **Проси чего хочешь** — нәрсә теләсәң шуны сора. **Хочешь не хочешь** или *простор ч.* **хоти не хоти** — теләсәң дә, теләмәсәң дә, телисеңме-теләмисеңме; *хочешь не хочешь, а идти надо* — телисеңме-теләмисеңме, барырга кирәк.

**ХОТЕ'ТЬСЯ** *несов. безл.*— ...-сы килү; *мне хочется домой* — минем өйгә кайтасым килә.

**ХОТЬ** —1. *союз уступительный* ... да, ... дә, гәрчә ... да, гәрчә ... дә; *хоть убей, не скажет* — үтерсәң дә әйтмәс; 2. *союз уступительный* кирәгем исә; *хоть живой в гроб ложись* — кирәгем исә тереләй кабергә кер; 3. *союз уступительный* — ...-мы; *хоть сегодня, хоть завтра, а идти надо* — бүгенме, иртәгәме, барыбер барырга кирәк; 4. *усилительная частица* теләсәң; хәтта; *жди хоть неделю* — теләсәң бер атна көт; 5. *усилительная частица* ичмасам, һич булмаса; *скажите хоть одно слово* — ичмасам бер генә сүз әйтегез; *дайте хоть три рубля* — һич булмаса өч тәңкә бирегез; 6. *разг. частица* мәсәлән, мисал өчен; *взять хоть этот случай за образец* — үрнәк итеп, мәсәлән, бу очракны алыйк; 7. *усилительная частица* булса да; *хоть кто* — кем булса да. ◇ **Хоть куда** —1. кая булса да; 2. *в знач. сказ.* бик шәп, бик яхшы; *парень хоть куда* — бик шәп егет. **Хоть бы** —1. ичмасам; *хоть бы слово сказал* — ичмасам бер сүз әйтсә иде; 2. ...-са иде; *хоть бы поскорей пришёл* — тизрәк килсә иде. **Хоть бы и так** *разг. фам.*— 1. шулай булсын ди, булса ни; 2. хәтта шулай булса да, алай булса да; 3. яхшы булыр иде. **Хоть и** — булса да, ... булуга карамастан; *утро было солнечное, хоть и холодное* — иртә салкын булса да кояшлы иде; *он хоть и стар, но крепок* — ул карт булуына карамастан, нык әле.

**ХОТЯ'** —1. *союз уступительный* к. хоть 1; 2. *союз противительный*, ...-са да; *он учился хорошо, хотя часто болел* — ул еш авырса да, яхшы укый иде; 3. *простореч.* к. хоть 2, 3, 4. ◇ **Хотя бы** —1. гәрчә, хәтта; *хотя бы ты и задумал войти, я тебе этого не позволю* — хәтта син барырга уйлаган булсаң да, мин сиңа рөхсәт итмәм; 2. мәсәлән, хәтта; *взять хотя бы такой факт* — мәсәлән, менә шушы фактны алыйк. **Хотя бы и так** *разг.*— к. хоть бы и так. **Хотя и** — к. хоть и. **Хотя и... но** — ...-са да, шулай да; *мальчик, хотя и смотрел на всех свысока, но товарищем был хорошим* — малай бар кешегә дә югарыдан караса да, яхшы иптәш иде.

**ХОХЛА'ТИТЬ** *несов. разг. фам.*— туздыру, тырпайту (чәчне һ. б.).

**ХОХЛА'ТКА** *несов. разг. фам.*—1. бүрекле кош; бүрекле тавык; 2. *зоол.* бүрекле күбәләк, чуклы баш күбәләк; 3. *бот.* сәрәнә, күке баш.

**ХОХЛА'ТЫЙ** —1. бүрекле; *хохлатые курицы* — бүрекле тавыклар; 2. (*лохматый*) йонлач, йөнтәс.

**ХОХЛА'Ч** *м.*— бүрекле кош.

**ХО'ХЛИТЬ** *несов.*— (йоннарын, канатларын) тырпайту, кабарту.

**ХО'ХЛИТЬСЯ** *несов.*—1. кабарыну, йоннарын (канатларын) тырпайту; 2. *перен. разг. фам.* чырае караңгылану.

**ХОХО'Л** *м.*—1. тырпаеп торган чәч толымы; 2. бүрек (кошларда).

**ХО'ХОТ** *м.*— шаркылдап көлү, шаркылдап көлү тавышы.

**ХОХОТА'ТЬ** *несов.*— шаркылдап көлү.

**ХОХОТЛИ'ВЫЙ** — шаркылдап көлүчән, шаркылдап көләргә ярата торган; *хохотливый человек* — шаркылдап көләргә ярата торган кеше.

**ХОХОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *разг. фам.*— к. хохот.

**ХОХОТУ'Н** *м.*, **ХОХОТУ'ШКА, ХОХОТУ'НЬЯ** *ж. разг.*— шаркылдык, шаркылдап көләргә яратучы кеше.

**ХО'ХРИТЬСЯ** *несов. простореч.*—1. к. хохлиться; 2. к. хорохориться.

**ХОХРЯ'К** *м. обл.*— шеш; бөкре.

**ХРАБРЕ'ТЬ** *несов. разг.*— батырлану, батырлана төшү, кыюлану, кыюлана төшү.

**ХРАБРЕ'Ц** *м.*— батыр кеше, кыю кеше.

**ХРАБРИ'ТЬ** *несов.*— кыюландыру, гайрәтләндерү.

**ХРАБРИ'ТЬСЯ** *несов. разг.*— батырлану, кыюлану, гайрәтләнү.

**ХРА'БРОСТЬ** *ж. мн.* нет — батырлык, кыюлык, гайрәтлелек.

**ХРА'БРЫЙ** — батыр, йөрәкле, кыю, гайрәтле.

**ХРАМ** *м.*—1. *церк.* храм, гыйбадәтханә; 2. *перен. ритор.* сарай; *храм науки* — фән сарае.

**ХРА'МИНА** *ж. книж. устар.*— бина, корылма.

**ХРАМОЗДА'ТЕЛЬ** *м. книж. торж. устар.*— гыйбадәтханә төзүче, гыйбадәтханәләр салдыручы.

**ХРА'МЫВАТЬ** *многокр. разг.*— аксаштыргалау.

**ХРАНЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — саклау; *камера для хранения багажа* — багаж саклау камерасы.

**ХРАНИ'ЛИЩЕ** *ср. книж. спец.*— саклау урыны.

**ХРАНИ'ТЕЛЬ** *м.*—1. *книж.* саклаучы, саклап торучы; 2. хранитель, хезмәткәр (китапханәләрнең, музейларның кайбер бүлекләрендә эшләүче хезмәткәр).

**ХРАНИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.*— саклый торган.

**ХРАНИ'ТЬ** *несов.*— саклау, саклап тоту, тоту; *хранить деньги в сберегательной кассе* — акчаны саклык кассасында тоту (саклау); *хранить тайну* — сер тоту; *хранить в памяти* — истә тоту. ◇ **Хранить молчание** — эндәшмәү, бер сүз дә әйтмәү. **Хранить печаль** — кайгыру, кайгылы булу. **Хранить гордый вид** — горур булу, горур кыяфәтле булу. **Хранить в тайне** — сер итеп саклау, әйтмәү.

**ХРАНИ'ТЬСЯ** *несов.*— саклану; *деньги хранятся в сберегательной кассе* — акча саклык кассасында саклана.

**ХРАП** I *м.*— 1. *только ед.* к. храпение; 2. *спец.* борын чиге (хайваннарда борын тишекләре арасының урта һәм түбән өлеше).

**ХРАП** II *м.*— храп (1. *тех.* механизмнарның хәрәкәт итә торган кисәкләрен туктата торган планка; 2. тәгәрмәч тормозы; 3. *спец.* судноларда йөк күтәрә торган ыргак).

**ХРАП** III *м. мн.* нет, *обл.*—1. бозлак, кар кабыгы, бозлавык (кар өстендә каткан юка боз катлавы); 2. күренде, калкулыклы боз.

**ХРАПЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — гырылдау, гырылдаган тавыш.

**ХРАПЕ'ТЬ** *несов.*—1. гырылдау, гырылдап йоклау; 2. *перен. простореч.* каты йоклау; 3. (*о животных*) пошкыру; *кони чуткие храпят* — сизгер атлар пошкыра.

**ХРАПНУ'ТЬ** *однокр. разг.*— гырылдап кую.

**ХРАПОВИ'К** *м. тех.*— храповик (валның бер генә якка әйләнүен тәэмин итә торган механизм).

**ХРАПОВИ'ЦКИЙ**: **задавать храповицкого** *разг. фам.*— гырылдап бик каты йоклау.

**ХРАПУ'Н** *м.*, **ХРАПУ'НЬЯ** *ж. простореч.*— гырылдап йоклаучан кеше.

**ХРЕБЕ'Т** *м.*—1. *анат.* арка сөяге, умыртка тезмәсе; 2. *перен. простореч.* арка; 3. *перен. разг.* җилкә; *всё вынес на своем хребте* — барысын да үз җилкәмдә татыдым; 4. *геогр.* сырт; тау тезмәсе. ◇ **Хребет дать** *устар.*— качу, табан ялтырату, качып китү, сыртны гына күрсәтү.

**ХРЕБЕ'ТНЫЙ** — к. хребтовый.

**ХРЕБТИ'НА** *ж. простореч.*— к. хребет 1.

**ХРЕБТО'ВЫЙ** —1. арка сөяге ...-ы; умыртка ...-ы; *хребтовые позвонки* — умыртка сөякләре; 2. сырт; *хребтовый мех* — сырт мехы. ◇ **Хребтовые перевалы** — тау тезмәләре аша кичү урыннары.

**ХРЕБТУ'Г** *м. обл.*— (атка ашату өчен солы салып тәртәгә бәйләп куела торган) солы капчыгы.

**ХРЕН** *м. мн.* нет — керән, керән тамыры. ◇ **Старый хрен** *разг. фам. пренебр.*— картлач. **Хрен редьки не слаще** — керән тормадан төче булмас.

**ХРЕНИ'НА** *ж. разг.*— керән тамыры.

**ХРЕНО'ВНИК** *м. с.-х.*— керән түтәле, керән үсә торган урын.

**ХРЕНО'ВЫЙ** — керән ...-ы; *хреновый запах* — керән исе.

**ХРЕСТОМАТИ'ЙНЫЙ** —хрестоматия...-ы; *хрестоматийный материал* — хрестоматия материалы.

**ХРЕСТОМА'ТИЯ** *ж.*— хрестоматия (төрле әсәрләрдән сайланып алынган өзекләрдән торган җыентык яки шул әсәрләрдән торган уку әсбабы).

**ХРИЗАНТЕ'МА** *ж.*— хризантема, алтын чәчәк (гөл).

**ХРИЗОБЕРИ'ЛЛ** *м. мин.*— хризоберилл (яшькелт төстәге асылташ).

**ХРИЗОБЕРИ'ЛЛОВЫЙ** — хризоберилл...-ы; хризоберилл (дан ясалган); *хризоберилловый перстень* — хризоберилл йөзек.

**ХРИЗОЛИ'Т** *м. мин.* — хризолит (асылташ).

**ХРИЗОЛИ'ТОВЫЙ** — 1. хризолит...-ы; *хризолитовый цвет*—хризолит төсе; 2. хризолит(тан ясалган); *хризолитовое кольцо*— хризолит балдак.

**ХРИЗОПРА'З** *м. мин.*—хризопраз (ярым асылташ, халцедонның бер төре).

**ХРИЗОТИ'Л** *м. мин.*— хризотил (җепсел минерал, азбестның бер төре).

**ХРИП** *м.*— 1. *только ед.* гыжлау; гырылдау; 2. гыжлаган тавыш; гырылдаган тавыш.

**ХРИПЕ'ТЬ** *несов.*— 1. гыжлау, гыжылдау; хырылдау; 2. *разг.* карлыккан тавыш белән сөйләү.

**ХРИПЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет— бераз карлыкканлык.

**ХРИПЛИ'ВЫЙ** — бераз карлыккан; *хрипливый голос* — бераз карлыккан тавыш.

**ХРИ'ПЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — карлыкканлык.

**ХРИ'ПЛЫЙ** — карлыккан; *хриплый голос* — карлыккан тавыш.

**ХРИ'ПНУТЬ** *несов.* — карлыгу; *голос хрипнет* — тавыш карлыга.

**ХРИПОТА'** *ж. мн.* нет — к. хрипеть 1.

**ХРИПУ'Н** *м.*, **ХРИПУ'НЬЯ** *ж. разг.*— карлыккан тавышлы кеше.

**ХРИСТАРА'ДНИК** *м. устар.*— хәерче, теләнче, сораначы.

**ХРИСТАРА'ДНИЧАТЬ** *несов. устар.*—хәер эстәү, теләнү, сорану.

**ХРИСТИАНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— христианлаштыру.

**ХРИСТИАНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— христианлаштыру.

**ХРИСТИАНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. книж.* — **1.** христианлашу; **2.** *страд.* христианлаштырылу.

**ХРИСТИАНИ'Н** *м.*, **ХРИСТИА'НКА** *ж.* — христиан (христиан динендәге кеше).

**ХРИСТИА'НСКИЙ** — христиан...-ы, христианнар...-ы; *христианская религия* — христиан дине. ◇ **Привести в христианский вид** *разг. шутл. устар.* — тәртипкә китерү, рәткә салу, тиешле хәлгә китерү.

**ХРИСТИА'НСТВО** *ср. мн.* нет — христианлык, христиан дине.

**ХРИСТИА'НСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — христиан динен тоту.

**ХРИСТО'В** *устар.*: **христова невеста** — 1. *устар.* монашка; **2.** карт кыз. ◇ **Христовым именем жить или перебиваться** *устар.* — хәер эстәп яшәү, хәер сорашып яшәү.

**ХРИСТОЛЮБИ'ВЫЙ** *церк. устар.* — христиан диненә нык ышанган.

**ХРИСТО'СОВАТЬСЯ** *несов. устар.* — пасха бәйрәме белән котлап өч тапкыр үбешү (христианнарда).

**ХРОМ** I *м. мн.* нет — хром (1. *хим.* каты эретмәләр, буяулар һ. б. әзерләгәндә кулланыла торган химик элемент, аксыл соры металл; **2.** *спец.* сары буяуның бер төре).

**ХРОМ** II *м. мн.* нет, *спец.* — хром (күннең бер төре).

**ХРОМАТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — хроматизм (1. *физ.* ак нурларның төрле төстәге нурларга таркалу сыйфаты; **2.** *муз.* музыкада тавышның ярым тоннарга бүленеп күтәрелә яки төшә баруы).

**ХРОМАТИ'Н** *м. мн* нет, *биол.* — хроматин (хайваннар яки үсемлекләр күзәнәге төшенең төсе үзгәрә ала торган төп матдәсе).

**ХРОМАТИ'ЧЕСКИЙ** — **1.** *физ.* хроматик; *хроматическое разложение лучей* — нурларның хроматик таркалышы; **2.** *муз.* хроматизмга нигезләнгән; *хроматическая гамма* — хроматизмга нигезләнгән гамма; **3.** хроматик (ярым тоннар чыгару өчен махсус җайланма куелган); *хроматические духовые инструменты* — хроматик тынлы кораллар.

**ХРОМА'ТЬ** *несов.* — **1.** аксау; чатанлау; *лошадь хромает* — ат аксый; **2.** *перен.* аксау; *у него хромает орфография* — ул орфографиядән аксый. ◇ **Хромать на обе ноги** *перен.* — җитешсезлекләр күп булу, ике аякка да аксау.

**ХРОМЕ'ТЬ** *несов.* — аксаклау, чатанлау.

**ХРОМЕ'Ц** *м. книж.* — аксак, аксак кеше, чатан.

**ХРОМИ'РОВАТЬ** *сов. и несов.* — хромлау, хром белән каплау (металлны).

**ХРОМИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — хромлану, хром белән каплану.

**ХРОМИРО'ВОЧНЫЙ** *тех.* — хромлау...-ы; хромлау өчен...; *хромировочный материал* — хромлау материалы.

**ХРО'МИСТЫЙ** *хим. мин.*, *тех.* — хромлы; *хромистая сталь* — хромлы корыч.

**ХРО'МОВЫЙ** I *хим.*, *тех.* — хромлы, хром катышкан; *хромовый экстракт* — хромлы экстракт.

**ХРО'МОВЫЙ** II *спец.* — **1.** хром...; *хромовая кожа* — хром күн; **2.** хром..., хромнан тегелгән; *хромовые сапоги* — хромнан тегелгән итек.

**ХРОМОГЕ'ННЫЙ** *науч.* — буяу матдәләре бирә торган, төс бирә торган.

**ХРОМОГРАВЮ'РА** *ж. тип.* — хромогравюра (литография ысулы белән басылган күп төсле басма).

**ХРОМО'Й** — **1.** аксак, чатан; *хромой человек* — аксак кеше; **2.** *в знач. сущ.* аксак кеше; **3.** *(о мебели)* аягы сынган; бер аягы кыска; *хромой стул* — аягы сынган урындык.

**ХРОМОЛИТОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** — хромолитография...-ы; *хромолитографический способ* — хромолитография ысулы.

**ХРОМОЛИТОГРА'ФИЯ** *ж.* — хромолитография (1. литографиядә күп төстә бастыру ысулы; **2.** литография ысулы белән күп төстә бастырылган басма).

**ХРОМОЛИТОГРА'ФСКИЙ** — хромолитографик; *хромолитографский способ* — хромолитографик ысул.

**ХРОМОНО'ГИЙ** — **1.** аксак, чатан; *хромоногий человек* — аксак кеше; **2.** к. хромой **3.**

**ХРОМОНО'ГОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — аксаклык, чатанлык.

**ХРОМОНО'ЖКА** *ж. разг.* — аксак хатын (кыз); аксак бала.

**ХРОМОСФЕ'РА** *ж. мн.* нет, *астр.* — хромосфера (кояш атмосферасының кояш тотылганда күренә торган кызыл алкасыман тышкы катлавы).

**ХРОМОТА'** *ж. мн.* нет — аксаклык, чатанлык, аксак булу.

**ХРОМОТИПИ'ЧЕСКИЙ** *тип.* — хромотипик.

**ХРОМОТИ'ПИЯ** *ж. тип.* — хромотипия (1. күп буяуда басып чыгару; **2.** шундый ысул белән басылган басма).

**ХРОМОФОТОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *ж. фот.* — хромофотографик.

**ХРОМОФОТОГРА'ФИЯ** *ж.* — хромофотография (**1.** *только ед.* төсле фотография ясау ысулы; **2.** төсле фотография).

**ХРОМУ'ША, ХРО'МУШКА** *м.* и *ж. разг. фам.* — аксак кеше, чатан кеше.

**ХРО'НИК** *м.*, **ХРОНИ'ЧКА** *ж. спец.* — хроник (озакка сузылган авырулы кеше).

**ХРО'НИКА** *ж.* — хроника (**1.** *истор.* вакыйгаларны хронологик тәртип белән язып бару; *русские хроники называются летописями* — рус хроникалары елъязмалар дип атала; **2.** *лит.* политик, иҗтимагый мөнәсәбәтләр, гаилә һ. б. мөнәсәбәтләр тарихын үз эченә алган әдәби әсәр; *семейная хроника* — гаилә хроникасы; **3.** *только ед.* газетада көндәлек вакыйгалар бүлеге; **4.** агымдагы көндәлек иҗтимагый тормышны чагылдырган кинофильм).

**ХРОНИКА'ЛЬНЫЙ** — хроника...-ы, хроникаль; *хроникальный фильм* — хроникаль фильм.

**ХРОНИКЕ́Р** *м.*, **ХРОНИКЕ́РША** *ж.* — хроникачы, хроника язучы, хроникёр (газета-

ның көндәлек хәбәрләр биреп тора торган хәбәрчесе).

**ХРОНИКЁРСКИЙ** — хроникёр...-ы; хроникачы...-ы; *хроникёрская заметка* — хроникёр заметкасы (кыскача мәкаләсе).

**ХРОНИ'СТ** *м. истор.* — хронист, хроника төзүче.

**ХРОНИ'ЧЕСКИЙ** — 1. хроник, озакка сузыла торган, озак дәвам итә торган; *хроническое заболевание* — озакка сузыла торган авыру. 2. хроник, озакка сузылган авыру белән авырый торган; *хронический больной* — хроник авыру.

**ХРОНО'ГРАФ** *м.* — хронограф (1. *истор.* бөтен дөнья тарихына һәм билгеле бер илнең хроникасына обзор ясап чыккан бик борынгы китап, язма; 2. *тех.* кыска вакытлы күренешләрнең дәвамлылыгын, мәсәлән, туп ядрәсенең очып баруының тизлеген, үлчәп үзе яза торган прибор).

**ХРОНОГРАФИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — хронограф...-ы, хронографик; *хронографическая запись* — хронографик язма, хронограф язмасы.

**ХРОНО'ЛОГ** *м. книж.* — хронолог (хронология белгече).

**ХРОНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — хронология...-ы, хронологик; *хронологические даты* — хронологик даталар; *письма, вошедшие в пятый том, расположены в хронологическом порядке* — бишенче томга кергән хатлар хронологик тәртиптә урнаштырылган.

**ХРОНОЛО'ГИЯ** *ж.* — хронология (1. вакыт эзлеклелеге сакланып язылган вакыйгалар исемлеге; 2. берәр нәрсәнең килеп чыгу вакыты яки килеп чыгуының эзлеклелеге; 3. вакыйгаларның датасын, документларның язылу вакытын билгели торган ярдәмче тарихи фән).

**ХРОНО'МЕТР** *м.* — хронометр (1. бик дөрес йөри торган кесә сәгате; 2. *спец.* бик дөрес йөри торган балансирлы астрономик сәгать).

**ХРОНОМЕТРА'Ж** *м. мн.* нет — хронометраж (берәр эшкә күпме вакыт киткәнен секундомер ярдәме белән тикшерү).

**ХРОНОМЕТРАЖИ'СТ** *м.*, **ХРОНОМЕТРАЖИ'СТКА** *ж.* хронометражист (берәр эшкә күпме вакыт киткәнен секундомер белән билгеләүче).

**ХРОНОМЕТРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — хронометражлау (хронометр ярдәме белән берәр эшне башкаруга күпме вакыт киткәнен билгеләү).

**ХРОНОМЕТРИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — хронометражлану.

**ХРОНОМЕТРИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — хронометрик; хронометр ярдәмендә...; *хронометрическое определение времени* — вакытны хронометр ярдәмендә билгеләү.

**ХРОНОСКО'П** *м. спец.* — хроноскоп (бик кыска вакыт арасын үлчи торган электрик сәгать).

**ХРОНОСКОПИ'ЧЕСКИЙ** — хроноскопик.

**ХРУП** *в знач. сказ. разг.* — шырт итте, шырт итеп ватылды, шытырт итте; *стекло хруп под ногою* — пыяла аяк астында шырт итте.

**ХРУ'ПАТЬ** *несов. разг.* — 1. шырт итеп ватылу; шытырт итеп ватылу; *от толчков хрупала посуда в ящике* — бәрелүдән тартмадагы савыт-саба шытырт-шытырт итеп ватыла иде; 2. шытырдатып ашау; *хрупать сахар* — шикәрне шытырдатып ашау.

**ХРУ'ПКИЙ** — 1. уалучан, тиз ватылучан; *хрупкая посуда* — тиз ватылучан савыт-саба; 2. *перен.* бик ябык, бик зәгыйфь; *хрупкая девушка* — бик зәгыйфь кыз.

**ХРУ'ПКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. уалучанлык, ватылучанлык, тиз ватылучанлык; 2. *перен.* зәгыйфьлек, ябыклык.

**ХРУ'ПНУТЬ** *однокр разг.* — шырт итеп кую, шытырдап кую, шытырт итү.

**ХРУСТ** *м. мн.* нет — шытырдау, чытырдау; шыгырдау; *хруст снега под ногами* — аяк астында карның шыгырдавы.

**ХРУСТА'ЛИК** *м. анат.* — хрусталик (күз ясмыгы).

**ХРУСТА'ЛЬ** *м.* — хрусталь (1. бик югары сыйфатлы пыяла; 2. шундый пыяладан ясалган савыт-саба). ◇ **Горный хрусталь** — тау хрустале (төссез үтә күренмәле минерал, оптик һәм ювелир әйберләр ясауда кулланыла). **Горные хрустали** *разг.* — тау хрусталеннән ясалган муенса.

**ХРУСТА'ЛЬНЫЙ** — 1. хрусталь...-ы; *хрустальный завод* — хрусталь заводы; 2. хрустальдән ясалган; хрусталь...; *хрустальная ваза* — хрусталь ваза; 3. *поэт* бик тонык, чиста; үтә күренеп тора торган; *хрустальная вода* — бик тонык су.

**ХРУ'СТАТЬ** *несов. обл.* — шытырдатып чәйнәү.

**ХРУСТЕ'ТЬ** *несов.* — кетердәү; шыгырдау; керт-керт итеп ашау; *снег хрустит под ногами* — кар аяк астында шыгырдый.

**ХРУ'СТНУТЬ** *однокр.* — шырт итү, шытырт итү, шытырдап кую, кетердәп кую.

**ХРУЩ** *м.* — май коңгызы.

**ХРЫЧ** *м. простореч. бран.*: **старый хрыч** — картлач, карт бүре.

**ХРЫЧО'ВКА** *ж. простореч. бран.* — карт пәри.

**ХРЮК** *м. разг.* — к. хрюканье.

**ХРЮ'КАЛО** *ср. простореч.* — 1. дуңгыз борыны; 2. *бран. (о человеческом лице)* дуңгыз борын, чучка борын.

**ХРЮ'КАТЬ** *несов.* — мырк-мырк итү, мыркылдау (дуңгыз).

**ХРЮ'КНУТЬ** *однокр.* — мыркылдап кую.

**ХРЮ'ШКА** *ж. разг.* — дуңгыз, чучка.

**ХРЯК** *м.* — ата дуңгыз.

**ХРЯ'ПА** *ж. мн.* нет, *обл.* — кәбестә яфраклары.

**ХРЯ'ПАТЬ** *несов. простореч. вульг.* — (комсызланып) авызны чапылдатып ашау.

**ХРЯ'ПКА** *ж.*, **ХРЯПО'К** *м. обл.* — к. кочерыжка.

**ХРЯСК** *м. мн.* нет, *обл.* — к. хряст.

**ХРЯ'СКАТЬ** *несов. обл.* — к. хрястать.

**ХРЯ'СКИЙ** *обл.* — янгыравыклы, көчле тавышлы, чапырдавыклы.

**ХРЯСТ** *м. мн.* нет, *обл.* — к. хруст.

**ХРЯ'СТАТЬ** *несов. обл.*— 1. кыйнау, тукмау; 2. к. хряпать.

**ХРЯ'СТНУТЬ** *однокр. обл.*— 1. кыйнап алу, тукмап алу; 2. ярылу, сыну; 3. к. хрястнуться.

**ХРЯ'СТНУТЬСЯ** *сов. обл.*— 1. егылу; *хрястнуться на пол* — идәнгә егылу; 2. бәрелү; *хрястнуться об дверь* — ишеккә бәрелү.

**ХРЯСТЬ** *в знач. сказ. обл.*— 1. сукты, утыртты; 2. егылды; 3. бәрелде.

**ХРЯЧО'К** *м. с.-х. обл.*— яшь ата дуңгыз.

**ХРЯЩ** I *м.*— кимерчәк; *носовой хрящ* — борын кимерчәге.

**ХРЯЩ** II *м.*— 1. *геол.* эре ком; 2. *обл.* калын тупас киндер.

**ХРЯЩЕВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — кимерчәклелек.

**ХРЯЩЕВА'ТЫЙ** I — кимерчәкле; *хрящеватое мясо* — кимерчәкле ит.

**ХРЯЩЕВА'ТЫЙ** II — эре комлы; *хрящеватая почва* — эре комлы туфрак.

**ХРЯЩЕВИ'К** *м. спец.*— кимерчәкле балык.

**ХРЯЩЕВИ'НА** *ж.*— 1. к. хрящ I; 2. *простореч.* кимерчәкле ит.

**ХРЯЩЕВО'Й** I — кимерчәк ...; *хрящевая ткань* — кимерчәк тукыма.

**ХРЯЩЕВО'Й** II — эре комлы; *хрящевой грунт* — эре комлы грунт.

**ХУ'ДЕНЬКИЙ** — 1. ябык кына, арык кына, бик ябык, бик арык; 2. бик иске, тузган, тузып беткән; *худенькое платье* — тузып беткән күлмәк.

**ХУДЕ'ТЬ** *несов.*— арыклану, ябыгу.

**ХУ'ДО** I *ср. мн.* нет — яманлык, начарлык; *никто тебе худа не пожелает* — синә беркем дә яманлык теләмәс.

**ХУ'ДО** II *нареч.*— 1. яман, начар; яманлык белән; *это может кончиться худо* — моның начар бетүе мөмкин; 2. *в знач. сказ. безл.* авыр, начар; *больному худо* — авыруның хәле начар.

**ХУДО'БА** *ж. мн.* нет, *собир. обл.*— милек, мал-мөлкәт.

**ХУДОБА'** *ж.*— чандырлык, арыклык, ябыклык.

**ХУДО'ЖЕСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — художестволылык.

**ХУДО'ЖЕСТВЕННЫЙ** — 1. художество ...-ы; сәнгать...-ы; *художественный руководитель театра* — театрның художество житәкчесе; *художественные школы* — сәнгать мәктәпләре; *художественная промышленность* — сәнгать промышленносте; 2. матур; әдәби; *художественная литература* — матур әдәбият; 3. нәфис; *художественное слово* — нәфис сүз; *художественная вышивка* — нәфис чигү.

**ХУДО'ЖЕСТВО** *ср.*— 1. сәнгать; *науки и художества* — фәннәр һәм сәнгатьләр; 2. *устар.* художество, сынлы сәнгать; 3. *разг. неодобр.* (*проделка, выходка*) начар эш, начар кыланыш.

**ХУДО'ЖНИК** *м.*— 1. художник (сәнгатьнең берәр өлкәсендәге ижат эшчесе — рәсем ясаучы, скульптор, архитектор, язучы һ. б.); 2. художник, рәссам (рәсемнәр ясаучы художник); 3. *перен.* художник (берәр нәрсәне зур зәвык белән, зур осталык белән башкаручы). ◇ **Классный художник** *дореврол.*— дәрәжәле художник (Художество академиясен зур көмеш медаль яки алтын медаль белән тәмамлаган кешеләргә бирелә торган исем). **Свободный художник** *дореврол.*— ирекле художник (1. Художество академиясен кечкенә көмеш медаль белән тәмамлаган кеше; 2. югары музыкаль белем алган музыкантларга бирелә торган исем).

**ХУДО'ЖНИЦА** *ж.*— к. художник 2.

**ХУДО'ЖНИЧЕСКИЙ** — художник ...-ы, рәссам...-ы, художниклык...-ы; рәссамлык...-ы; *художнические способности* — художниклык сәләтләре.

**ХУДО'ЖНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *устар.*— художниклык, рәссамлык.

**ХУДО'Е** *ср. в знач. сущ.*— яманлык, начарлык; *он никому ничего худого не делал* — аның беркемгә дә начарлык эшләгәне юк.

**ХУДО'Й** — 1. арык, ябык, чандыр; *худа она была, как скелет* — ул скелет кебек ябык иде; 2. тишек, ертык; *худой карман* — тишек кесә; 3. бозык; *худые зубы* — бозык тешләр; 4. начар; *худые корма* — начар терлек азыклары. ◇ **На худой конец** — к. конец. **Не говоря худого слова** *разг. фам.*— бернәрсә дә әйтмичә, эндәшмичә генә, эндәшми-нитми.

**ХУДОКО'ННЫЙ** *устар. обл.*— алама атлы, начар атлы.

**ХУДОРО'ДНЫЙ** *устар.*— ярлы нәселдән булган, затлы нәселдән булмаган.

**ХУДОРО'ДСТВО** *ср. устар.*— ярлы нәселлелек, затлы нәселдән булмау.

**ХУДОСО'ЧИЕ** *ср. мн.* нет — ябыклык, бетерешкәнлек, чирләшкәлек, хәлсезлек.

**ХУДОСО'ЧНЫЙ** — бетерешкән, чирләшкә, ябык.

**ХУ'ДОСТЬ** *ж. мн.* нет, *устар.*— ярлылык.

**ХУДОШЁРСТНЫЙ** *разг.*— начар йонлы.

**ХУДОЩА'ВОСТЬ** *ж.*— ябыклык, арыклык, чандырлык.

**ХУДОЩА'ВЫЙ** — ябык, арык, чандыр.

**ХУ'ДШИЙ** — 1. аламарак, начаррак; 2. иң начар, иң алама. ◇ **В худшем случае** — актык чиктә.

**ХУДЫ'ШКА** *ж. разг. фам.*— бик ябык бала, бик арык бала, бик чирләшкә бала.

**ХУ'ЖЕ** — начаррак, аламарак.

**ХУЖЕ'ТЬ** *несов. обл.*— начарлану, аламалану; ябыгу, арыклану.

**ХУЛА'** *ж. книж.*— тиргәү, шелтә.

**ХУЛИГА'Н** *м.*— хулиган.

**ХУЛИГА'НИТЬ** *несов.*— хулиганлык итү, хулиганлану.

**ХУЛИГА'НСКИЙ** — хулиганнарча, хулиган...-ы; хулиганнар...-ы; *хулиганское поведение* — үзен хулиганнарча тоту; *хулиганская выходка* — хулиганнар кыланышы.

**ХУЛИГА'НСТВО** *ср. мн.* нет — хулиганлык.

**ХУЛИГА'НСТВОВАТЬ** *несов.*— хулиганлык итү.

**ХУЛИГАНЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир.*— хулиганнар.

**ХУЛИ'ТЕЛЬ** *м. книж. ритор.*— хурлаучы, яманлаучы.

**ХУЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.*— тиргәү...-ы; яманлау...-ы; *хулительные речи* — яманлау речьләре.

**ХУЛИ'ТЬ** *несов.*— яманлау, хурлау, тиргәү.

**ХУ'НТА** *ж.*— хунта (испан телендә сөйләшүче илләрдә төрле союзларның, берләшмәләрнең исеме).

**ХУНХУ'З** *м.*— хунхуз (феодаль-буржуаз Кытайдагы кораллы бандитлар отряды әгъзасы).

**ХУРА'Л** *м.*— хурал (Монголия Халык Республикасында сайланып куелган җирле һәм югары власть органнарының исеме).

**ХУРМА'** *ж.*— хөрмә (агачы һәм җимеше).

**ХУРУЛДА'Н** *м.*— к. хурал.

**ХУ'ТОР** *м.*— хутор (хуҗасының йорты белән бергә аерым җир участогы).

**ХУ'ТОРНЫЙ** — хутор...-ы; *хуторные постройки* — хутор каралтылары.

**ХУТОРСКО'Й** — хутор...-ы; *хуторское хозяйство* — хутор хуҗалыгы.

**ХУТОРЯ'НИН** *м.*— 1. хуторда яшәүче; 2. хутор биләүче, хутор хуҗасы.

**ХУТОРЯ'НКА** *ж.*— хуторда яшәүче хатын, хуторда яшәүче кыз.

# Ц

**ЦАЛОВА'ТЬ, ЦАЛОВА'ТЬСЯ** *несов. устар.*— к. целовать, целоваться.

**ЦА'НГА** *ж. тех.*— цанга (станокта эшкәртелә торган әйберне кыстыру өчен пружиналы җайланма, кыстыргыч).

**ЦАП** *в знач. сказ. простореч.*— эләктерде, каптырды; тотты, ябышты, эләктереп алды; *кто-то цап за плечо: „держи вора!“ кричит* (Некрасов) — кемдер җилкәсеннән эләктереп ала да: „тотыгыз каракны!“ дип кычкыра.

**ЦА'ПАТЬ** *несов. простореч.*— 1. ышкылу, сыдыру, тию; *дверь цапает пол* — ишек идәнгә ышкыла; 2. тырнау, тырнакларын батыру; *кошка цапает руку* — мәче кулны тырный; 3. тартып алу, тотып алу, эләктерү, ябышу; *цапать из рук* — кулдан тартып алу; *цапать за плечо* — җилкәдән эләктерү, җилкәгә ябышу, җилкәдән тотып алу; 4. чалт итеп сугу, ору, кундыру.

**ЦА'ПАТЬСЯ** *несов. простореч.*— 1. (*царапаться*) тырнашу, тырнау, тырнакларын батыру; 2. *перен.* әрләшү, оршышу, талашу, ызгышу; *цапаться из-за пустяков* — бер дә юкка әрләшү.

**ЦА'ПИНА** *ж. простореч.*— к. царапина.

**ЦА'ПКА** *с.-х.*— кечкенә китмән, тәпке (туфрак йомшарткыч корал).

**ЦА'ПКИЙ** *простореч.*— нык ябышучан, эләктерүчән; *белка цапка* — тиен (тырнаклары белән) бик нык ябышучан.

**ЦАПКОВА'ТЬ** *несов.*— 1. *с.-х.* туфракны китмәнләү; китмәнләп йомшарту, тәпкеләү; 2. *тех. спец.* (*формовать торф*) торф кисү, кирпеч-кирпеч итеп кискәләү.

**ЦА'ПКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *простореч.*— нык эләктерүчәнлек, тотынучанлык, ябышучанлык.

**ЦА'ПЛЯ** *ж.*— челән.

**ЦА'ПНУТЬ** *однокр. простореч.*— к. цапать.

**ЦАПОНЛА'К** *м. спец.*— цапонлак, кәгазьлагы (бозылудан саклау максаты белән, кыйммәтле кәгазьләрнең һәм металл эшләнмәләрнең өстенә йөгертү өчен кулланыла торган үтә күренмәле лак).

**ЦА'ПФА** *ж.*— цапфа (1. *тех.* валның яки күчәрнең подшипникка ышкылып әйләнә торган чыгынтысы, очы яки муентыгы; 2. *воен.* туп көпшәсендә лафет уемына кереп утыра торган кечкенә чыгынты). ◇ **Поворотная цапфа** — боргыч цапфа (автомобильнең алгы көпчәген бора торган җайланма).

**ЦА'ПФЕННЫЙ** *тех. воен.*— цапфа...-ы; *цапфенное гнездо в лафете* — лафеттагы цапфа оясы.

**ЦАП-ЦАРА'П** *в знач. сказ. разг. фам.*— эләктерде, эләктереп (каптырып) алды; *лиса петуха цап-царап* — төлке әтәчне эләктереп алды.

**ЦАРА'П** *в знач. сказ. разг.*— тырнап алды, тырнап җибәрде.

**ЦАРА'ПАТЬ** *несов.*— 1. тырнау; *кошка царапает руку* — песи кулны тырный; 2. тырнау; тырнап язу, чокып язу; *перо царапает* — каләм тырный (тырнап яза); *царапать буквы на стене* — стенага (очлы нәрсә белән) тырнап хәрефләр язу; 3. (берәр нәрсә белән тырнап) сызу; *царапать зеркало гвоздем* — көзгегә кадак белән сызу; 4. *разг. шутл. пренебр.* сызгалау, кәкре-бөкре язу, белер-белмәс язу; *царапать письмо* — хат сызгалау.

**ЦАРА'ПАТЬСЯ** *несов.*— 1. тырнау; *кошка царапается* — мәче тырный; 2. тырнашу, бер-берсен тырнау; *кошки царапаются* — мәчеләр тырнашалар; 3. *перен. разг. фам.* (*браниться*) бер-берсе белән әрләшү, чәйнәшү, ызгышу, оршышу; 4. *обл.* к. царапкаться.

**ЦАРА'ПИНА, ЦАРА'ПИНКА** *ж.* — тырналган эз, җәрәхәт эзе, тырнак эзе, сыдырылган урын.

**ЦАРА'ПКА** — 1. *м.* и *ж. разг. детск.* тырна(ш)уҹан кеше; 2. *ж. спец.* кабык төшергеч, каезлагыч (агач кабыгын төшерү, каезлау өчен тимер тешләр кагылган корал).

**ЦАРА'ПКАТЬСЯ** *несов. обл.* — к. карабкаться.

**ЦАРА'ПНУТЬ** *однокр. сов.* — тырнап алу.

**ЦАРЁВ** *простореч.* — к. царский 1.

**ЦАРЕ'ВИЧ** *ж.* — патша улы; *Иван-царевич (нар. сказочн.)* — патша улы Иван (рус халык әкиятләренең каһарманы).

**ЦАРЕ'ВНА** *ж.* — патша кызы.

**ЦАРЕДВО'РЕЦ** *м. книж. устар.* — сарай әһеле, сарай хезмәткәре.

**ЦАРЕУБИ'ЙСТВО** *ср. книж. устар.* — патша үтерү.

**ЦАРЕУБИ'ЙЦА** *м. книж. устар.* — патшаны үтерүче, падишаһны үтергән кеше.

**ЦАРИ'ЗМ** *м. мн.* нет — царизм, патшалык строе (патша идарә иткән политик төзелеш).

**ЦАРИ'СТСКИЙ** *книж.* — царизм (патшалык) ...-ы; патша строе ...-ы; *царистская политика* — царизм политикасы.

**ЦАРИ'ТЬ** *несов.* — 1. *устар.* к. царствовать 1; 2. *перен.* хөкем сөрү, киң таралган (җәелгән) булу, ...-ган булу; *везде царило необычайное оживление* — һәр җирдә искиткеч җанлану хөкем сөрә иде; *над деревней сон непробудный царил* — авыл тирән йокыга талган иде; 3. *перен. книж.* өстенлек итү; өстен булу.

**ЦАРИ'ЦА** *ж.* — 1. *(жена царя)* патша хатыны; 2. *(царствующая женщина)* хатын патша; 3. ...күрке, иң гүзәл хатын-кыз; *она была царицей петербургского света* (Л. Толстой) — ул Петербург югары җәмгыятенең күрке иде.

**ЦА'РСКИЙ** — 1. патша...-ы; *царский указ* — патша указы (фәрманы); 2. *полит.* патшалык (царизм) ...-ы; *царский режим* — патшалык режимы; 3. *перен. устар.* зиннәтле асыл; бик шәп, менә дигән. ◇ **Царская водка** — „патша аракысы", алтын суы (азот һәм тоз кислоталарының кушылмасы, алтын эретә торган матдә). **Царские врата** *церк.* — чиркәүдә тәре бүлмәсенең урта ишеге.

**ЦА'РСТВЕННО** *нареч.* — мәгъръур рәвештә, мәһабәт рәвештә, горур.

**ЦА'РСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.* — мәһабәтлек, мәгъруурлык.

**ЦА'РСТВЕННЫЙ** *книж. устар.* — 1. к. царский 1; 2. *перен.* мәгъръур, горур, мәһабәт; *царственная поступь* — мәһабәт йөреш.

**ЦА'РСТВИЕ** *ср. устар.* — к. царство. ◇ **Царствие небесное** *устар. рел.* — җәннәт, оҗмах; *царствие ему небесное* — урыны оҗмахта булсын.

**ЦА'РСТВО** *ср.* — 1. патшалык (патша идарә итә торган дәүләт); 2. к. царствование; 3. *перен.* дөнья; *растительное царство* — үсемлекләр дөньясы (флора); *животное царство* — хайваннар дөньясы (фауна). ◇ **Сонное царство** *разг. шутл.* — йокы дөньясы (йокыга талган бик күп кешеләр турында көлеп әйтелә). **Царство небесное** — к. царствие небесное.

**ЦА'РСТВОВАНИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. царствовать; 2. патшалык иткән заман, патша булган чор; *в царствование Петра I* — Пётр беренче патшалык иткән заманда.

**ЦА'РСТВОВАТЬ** *несов.* — 1. *(быть царем)* патшалык итү, патша булып тору; 2. *перен. шутл. ирон. (управлять)* патшалык итү, идарә итү, эш йөртү; 3. *книж.* к. царить; *царствовало глубокое молчание* — тирән тынлык хөкем сөрә иде.

**ЦАРЬ** *м.* — патша, падишаһ; *царь зверей* — җанварлар патшасы (арслан); *царь деревьев* — агачлар патшасы (имән). ◇ **Царь-птица** *фольк.* — кошлар патшасы (бөркет, каракош). **Царь-пушка** — царь-пушка (Мәскәү Кремлендә саклана торган борынгыдан калган бик зур пушка). **Царь-колокол** — царь-колокол (шулай ук Мәскәү Кремлендәге тарихи истәлек буларак саклана торган бик зур кыңгырау, чаң). **Царь-дерево** — баобаб агачы. **Царь-девица** *фольк.* — кызларның солтаны (иң гүзәле). **Царь в голове** *у кого-н.* или **с царем в голове** *разг.* — башында акылы булу, башы булу. **Без царя в голове** *разг.* — акылсыз, акылы зәгыйфь булу, башы эшләмәү. **При царе Горохе** — борын-борын заманда, хан заманында.

**ЦА'ЦА** *ж.* — 1. уенчык, бала уенчыгы; 2. *простореч. фам. пренебр.* назлыбикә, иркә, кыланчык.

**ЦА'ЦКА** *ж.* — к. цаца.

**ЦА'ЦКАТЬСЯ** *несов. простореч.* — (берәү белән) артык әвәрә булу; мәш килү; мәшәкатьләнү; артык булашу (ярарга тырышып).

**ЦВЕЛЬ** *ж. мн.* нет, *обл.* — күгәрек.

**ЦВЕСТИ'** *несов.* — 1. *книж.* яшәрү, үсү, җәйрәп үсеп утыру; 2. чәчәк ату; чәчәк ачылу, чәчәктә утыру; *яблони цветут* — алмагачлар чәчәк ата; 3. серкә очыру; *рожь цветёт* — арыш серкә очыра; 4. *перен. (о человеке)* чәчәк кебек, гөл кебек булу, сау-сәламәт булу; 5. *перен. книж.* гөрләп чәчәк ату, алга китү, алга бару, үсү; *цветут науки и искусства* — фән һәм сәнгать гөрләп чәчәк ата; 6. *(о воде)* бака ефәге белән каплану, яшел басу, күгәрү (вак организмнар, суүсемнәр һәм күгәрекләр белән капланып яшелләнү); 7. *обл. (о лице)* бетчә басу, сыткы басу.

**ЦВЕТ** *м.* — 1. (*мн.* цвета́) төс; *яркий цвет* — ачык төс; 2. (*мн.* цветы́) чәчәк, чәчкә, гөл; *полевые цветы* — кыр чәчәкләре, чәчкәләр; 3. *перен. книж.* „чәчкәсе", иң яхшы өлеше; *цвет молодежи* — яшьләрнең иң шәпләре, яшьләрнең „чәчкәсе". ◇ **В (во) цвете** (лет, сил и т. п.) — (гомеренең, көч-сәләтенең) гөрләп чәчәк аткан вакытында, тулы үсеше чорында; *погиб во цвете лет* (сил) — тормышы (та-

ланты) гөрләп чәчәк атканда һәлак булды. **В цвету** — шау чәчәктә, чәчәк атып утыра; *сад весь в цвету* (Фет) — бакча шау чәчәктә (чәчәк атып утыра). **Срывать цветы удовольствия** — к. срывать I.

**ЦВЕ'ТЕНЬ** *м.* — серкә, чәчәк тузаны.

**ЦВЕ'ТИК** *м. нар.-поэт.* — цветочек.

**ЦВЕТИ'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. артык күп чәчәкле (бизәкле) булу; 2. артык чуарлык, күпертелгәнлек (стиль турында).

**ЦВЕТИ'СТЫЙ** — 1. чуар, (төрле) бизәкле, төрле төсле, аллы-гөлле; 2. *перен. неодобр. (витиеватый)* артык чуарланган, күпертелгән (язу стиле турында).

**ЦВЕТИ'ТЬ** *несов. разг.* — 1. *(пестро раскрашивать)* төрле төскә буяу, чуарлап бизәү; төрле төскә кертү; 2. *перен.* (җөмләне) артык купшыландыру, күпертү, чачаклы-чуклы сүзләр белән язу.

**ЦВЕТКО'ВЫЙ** *бот.* — чәчәкле (чәчәк ярдәмендә үрчи торган); *цветковые растения* — чәчәкле үсемлекләр.

**ЦВЕТНЕВО'Й** *бот.:* **цветневая пора** — серкәләнү чоры.

**ЦВЕТНИ'К** I *м.* — 1. чәчәклек, чәчәк бакчасы, чәчәк түтәле; 2. *перен разг.* гөлбакча (бер төркем гүзәл ханымнар, сөйкемле балалар һ. б.); 3. *истор. лит.* гөлстан, бостан (күңелле һәм файдалы уку җыентыклары).

**ЦВЕТНИ'К** II *м. спец.* — төсле металлургия промышленностенда эшләүче (эшче, белгеч).

**ЦВЕТНО'Й** — 1. төсле (ак һәм карадан башка төстәге); *цветные металлы* — төсле металлар (тимердән һәм аның коелмаларыннан башка металлар); *цветное кино* — төсле кино; 2. *(о людях)* төсле, кара тәнле, сары тәнле (ак тәнле булмаган); *дискриминация цветного населения в Америке* — Америкада кара тәнлеләрне дискриминацияләү.

**ЦВЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — төрле төслелек, чуарлык; төрле чәчәкле (бизәкле, парчалы) булу.

**ЦВЕТОВО'Д** *м. спец.* — чәчәк үстерүче, чәчәк үстерү белән шөгыльләнүче (белгеч яки һәвәскәр бакчачы).

**ЦВЕТОВО'ДСТВО** *ср. спец.* — 1. *только ед.* чәчәкчелек, чәчәк (гөл) үстерүчелек; 2. чәчәк (гөл) үстерү хуҗалыгы.

**ЦВЕТОВО'ДЧЕСКИЙ** *книж.* — чәчәкчелек...-ы; чәчәк (гөл) үстерү ...-ы; чәчәкчелек белән шөгыльләнүче; *цветоводческое хозяйство* — чәчәкчелек хуҗалыгы, чәчәк үстерү хуҗалыгы,

**ЦВЕТОВО'Й** — төс (ләр) ...-ы; *цветовые ощущения* — төс сиземнәре; *цветовой контраст* — төсләр контрасты. ◇ **Цветовая слепота** — к. дальтонизм.

**ЦВЕТОЕ'Д** *м. зоол.* — чәчәкашар, чәчәк коңгызы (корткыч бөҗәк).

**ЦВЕТО'К** *м. бот.* (мн. **цветы, цветки**) — 1. чәчәк, чәчкә; гөл; *сорвать цветок* — чәчәк өзү; *живые цветы* — тере (табигый) чәчәкләр; *искусственные цветы* — ясалма чәчәкләр, кәгазь чәчәкләр; *полевые цветы* — кыр чәчкәләре; 2. *поэт.* берәр нәрсәнең чәчкәсе (иң яхшы өлеше, иң яхшы үрнәкләре); *поэзии цветы* — шигърият чәчкәләре.

**ЦВЕТОЛО'ЖЕ** *ср. бот.* — чәчәк төбе, чәчәк түшәге, чәчәк ятагы.

**ЦВЕТОЛЮ'Б** *м. зоол.* — чәчәкләч (черек агач коңгызы).

**ЦВЕТОНО'ЖКА** *ж. бот.* — чәчәк сабы, гөл сабагы.

**ЦВЕТОНО'СНЫЙ** *бот.* — чәчәк ата торган; *цветоносное растение* — чәчәк ата торган үсемлек.

**ЦВЕТО'ЧЕК** *м.* — чәчкә, чәчәк, гөл, гөлкәй; *аленький цветочек* — алсу гөл; *приколоть цветочек* — чәчәк кадап кую. ◇ **Это только (или еще) цветочки** *разг. перен.* — бу әле баласы гына; *это еще цветочки, а ягодки впереди* — бу әле аның баласы, мичтә калгандыр анасы.

**ЦВЕТО'ЧНИК** *м.* — 1. чәчәк үстерүче, гөл үстерүче; 2. чәчәк ясаучы (кәгазьдән); 3. чәчәк сатучы.

**ЦВЕТО'ЧНИЦА** *ж.* — 1. к. цветочник I; 2. *зоол.* чәчәк чебене (авыл хуҗалыгы өчен зарарлы чебен төре).

**ЦВЕТО'ЧНЫЙ** — 1. чәчәк ...-ы; *цветочная почка* — чәчәк бөресе; 2. гөл...-ы; *цветочный горшок* — гөл чүлмәге; 3. чәчәк сата торган, чәчәк ...-ы; *цветочный магазин* — чәчәк сата торган магазин, чәчәк кибете; 4. чәчәктән ясалган (алынган).

**ЦВЕТУ'ХА** *ж. бот.* — иртә чәчәкләнү (икенче елында гына чәчәкләнә торган икееллык үсемлекнең беренче елда ук чәчәк сабагы чыгаруыннан гыйбарәт булган үсемлек авыруы).

**ЦВЕТУ'ЩИЙ** — 1. чәчәк чыгарган; чәчәк аткан, шау чәчәктә утыра торган; *цветущий сад* — шау чәчәктә утыра торган бакча; 2. *перен.* гөрләп чәчәк аткан, алга киткән; *Татария — цветущая советская республика* — Татарстан — алга киткән (чәчәк аткан) совет республикасы.

**ЦВИН** *м. сапож.* — цвин (теккәндә итекне калыпка беркетү өчен, вакытлы рәвештә итек үкчәсенә сугыла торган кадак).

**ЦЕ'ВКА** *ж.* — 1. *обл.* көпшә, трубкасыман куыш нәрсә; 2. *спец.* шүре; 3. *обл.* к. коклюша; 4. *спец. (лучевая кость)* шүре сөяк, орчык сөяк; 5. *спец.* (у лошади) бәкәл сөяге; 6. *тех.* (тешле тәгәрмәчләрдәге) чыгынты, теш.

**ЦЕ'ВКОВЫЙ** — к. цевочный.

**ЦЕВНИ'ЦА** *ж. старин. поэт.* — курай, сорнай.

**ЦЕ'ВОЧНЫЙ** — тешле; *цевочное колесо* — тешле тәгәрмәч; *цевочная передача* — тешле тапшыргыч.

**ЦЕВЬЁ** *ср. спец.* — 1. сап; 2. *(у ружья)* цевьё, көбәк.

**ЦЕДИ'ЛКА** *ж. разг.* — сөзгеч.

**ЦЕДИ'ЛЬНЫЙ** — (сөт һ. б.) сөзгеч, сөзә торган, сөзү ...-ы; *цедильная марля* — сөзә торган марля (бүз).

**ЦЕДИ'ЛЬЩИК** *м.* — (сөт һ. б.) сөзүче.

**ЦЕДИ'ТЬ** *несов.* — 1. сөзү, сөзгечтән үткәрү; 2. әкрен генә агызу, саркыту; 3. *перен. разг.* теш арасыннан сөйләү, ирен-неп кенә сөйләү; *цедить слова* — сүзләрен теш арасыннан гына чыгарып сөйләү.

**ЦЕДИ'ТЬСЯ** *несов. страд.* — сөзелү, саркытылу, сыгылу.

**ЦЕ'ДРА** *ж. мн.* нет — цедра (лимон яки әфлисун кабыгының киптереп вакланган кисәкләре, аш тәмләткеч сыйфатында кулланыла).

**ЦЕЖ** *м. мн.* нет, *спец.* — сөзелмә, саркынты, сыгымта; *рисовый цеж* — дөге сөзелмәсе (дөге шулпасы).

**ЦЕ'ЖИВАТЬ** *многокр. разг.* — (күп мәртәбә) сөзү, саркыткалау, сөзгәләү.

**ЦЕ'ЗИЙ** *м. мн.* нет, *хим.* — цезий (көмеш төсле аксыл һәм йомшак металл, химик элемент).

**ЦЕЗУ'РА** *ж. лит. муз.* — цезура (шигырь юллары эчендә яки музыкада ритмик төркемнәр аралыгы; ритмик тукталыш, ритмик пауза).

**ЦЕЙТЛУ'ПА** *ж. спец.* — цейтлупа (секундына 200 ләп кадр төшерә торган куәтле кино төшерү аппараты).

**ЦЕЙТНО'Т** *м. мн.* нет, *шахм.* — цейтнот (шахмат уенында чираттагы йөрешне уйларга вакыт калмау).

**ЦЕЙХГА'УЗ** *м. воен.* — цейхгауз (гаскәр кирәк-яраклары саклана торган склад).

**ЦЕЛЕ'БНОСТЬ** *ж.* — шифалылык, дәвалылык хасияте; файдалылык, төзәтүчәнлек.

**ЦЕЛЕ'БНЫЙ** — шифалы, файдалы; дәвалый (савыктыра, терелтә) торган, савыктыргыч, сәламәтлекне ныгыта торган; *целебные воды* — шифалы сулар.

**ЦЕЛЕВО'Й** — 1. билгеле бер максатны күздә тоткан, билгеле бер максат өчен билгеләнгән; *целевой аванс* — билгеле бер максатка билгеләнгән аванс; 2. максат...-ы; *целевая установка доклада* — докладның максат куелышы (докладның алдына куйган максаты, исәбе).

**ЦЕЛЕНАПРА'ВЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. псих.* — максат юнәлеше, максатка юнәлтелгәнлек.

**ЦЕЛЕНАПРА'ВЛЕННЫЙ** — максатлы, максат белән..., билгеле бер максат күзәткән, максатка юнәл(тел)гән; *целенаправленные действия* — билгеле бер максат белән эш итү (максатча эш итү).

**ЦЕЛЕСООБРА'ЗНОСТЬ** *ж. мн.* нет — максатчалык, максатка ярашлылык.

**ЦЕЛЕСООБРА'ЗНЫЙ** — максатча; максатка ярашлы, максатка туры килә торган.

**ЦЕЛЕУСТРЕМЛЁННОСТЬ** *ж. мн.* нет — максатка омтылышлылык, максатка юнәлтелгәнлек.

**ЦЕЛЕУСТРЕМЛЁННЫЙ** — максатка омтылышлы, максатка юнәл(тел)гән, максатлы; *целеустремлённые действия* — максатлы хәрәкәтләр.

**ЦЕЛИЗНА'** *ж. мн.* нет, *старин.* — к. целина.

**ЦЕЛИ'К** I *м. обл. спец.* — 1. бөтен нәрсә, тоташ кисәк; 2. *горн.* (шахталарда) тау токымының үзеннән калдырылган терәк, ныгытма; 3. (*непаханая земля*) сабан-сука тимәгән чирәм жир; 4. (*девственный лес*) кеше аягы басмаган урман.

**ЦЕЛИ'К** II *м. воен.* — целик (туп һәм пулемётларда прицелның күчерелмә өлеше).

**ЦЕЛИКО'М** *нареч.* — 1. бөтенләй, бөтенләтә, бөтен көе, бөтен килеш; *проглотил кусок целиком* — бер кисәкне бөтен көе капты да йотты; 2. тулысынча, һәрьяклап, тәмам, жаны-тәне белән; *он целиком отдался науке* — ул бөтен жаны-тәне белән фәнгә бирелгән. ◇ **Целиком и полностью** — тулысынча, бөтенләй, тәмам; *целиком и полностью одобрить решения съезда* — съездның карарларын тулысынча яхшы дип табу.

**ЦЕЛИНА'** *ж. мн.* нет — 1. чирәм жир; 2. *перен.* кеше аяк басмаган урыннар, кыргый дала, сахра; *снежная целина* — тоташ кар сахрасы.

**ЦЕЛИ'ННЫЙ** — 1. чирәм жир ...-ы; *целинный участок* — чирәм жир участогы; 2. (*девственный*) кул тимәгән, аяк басмаган; табигый, кыргый.

**ЦЕЛИ'ТЕЛЬ** *м. книж.* — дәвалаучы, терелтүче, савыктыручы.

**ЦЕЛИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — к. целебность.

**ЦЕЛИ'ТЕЛЬНЫЙ** — шифалы, савыктыргыч; *целительный воздух* — шифалы һава, савыктыргыч һава.

**ЦЕ'ЛИТЬ** *несов.* — 1. (*в цель*) төзәү, төбәү, турылау; юнәлтү, юнәлдерү (мылтыкны); *целить в мишень* — мишеньга төзәү; 2. *перен. разг.* к. метить II 2, 3.

**ЦЕЛИ'ТЬ** *несов. книж. устар.* — дәвалау, терелтү, савыктыру, сәламәтләндерү, дәвалап тергезү.

**ЦЕ'ЛИТЬСЯ** *несов.* — к. целить 1.

**ЦЕЛКА'Ч**, **ЦЕЛКА'Ш** *м. простореч. вульг.* — к. целковый.

**ЦЕЛКО'ВИК** *м. простореч. фам.* — к. целковый.

**ЦЕЛКО'ВЫЙ** *м. простореч.* — бер сум(лык) акча; бер тәңкә (көмеш акча).

**ЦЕЛЛОФА'Н** *м. мн.* нет, *спец.* — целлофан (әйбер төрү өчен кулланыла торган целлюлоид кәгазьсыман плёнка).

**ЦЕЛЛОФА'НОВЫЙ** *спец.* — 1. целлофан...-ы; *целлофановый цех* — целлофан цехы; 2. целлофан(нан ясалган); *целлофановая обёртка* — целлофан төргәк.

**ЦЕЛЛУЛО'ЗА** — к. целлюлоза.

**ЦЕЛЛУЛО'ЗНЫЙ** — к. целлюлозный.

**ЦЕЛЛУЛО'ИД** *м. мн.* нет — целлулоид (целлюлозадан хәзерләнгән эластик матдә; киноленталар һәм фотопластинкалар эшләү өчен кулланыла).

**ЦЕЛЛУЛО'ИДНЫЙ**, **ЦЕЛЛУЛО'ИДОВЫЙ** — целлулоид...-ы; целлулоидтан ясалган; *целлулоидные игрушки* — целлулоид уенчыклар, целлулоидтан ясалган уенчыклар.

**ЦЕЛЛЮЛО'ЗА** *ж.*— 1. *бот.* к. клетчатка 1; 2. целлюлоза (агач һәм үсемлек сабакларыннан химик юл белән эшкәртелеп алына торган һәм кәгазь, ясалма ефәк, шартлаучы әйберләр ясауга китә торган синтетик матдә).

**ЦЕЛЛЮЛО'ЗНО-БУМА'ЖНЫЙ: целлюлозно-бумажная промышленность** — целлюлоза-кәгазь промышленносте.

**ЦЕЛЛЮЛО'ЗНЫЙ** — целлюлоза...-ы; *целлюлозная фабрика*— целлюлоза фабрикасы.

**ЦЕЛЛЮЛО'ИД** — к. целлулоид.

**ЦЕЛЛЮЛО'ИДНЫЙ** — к. целлулоидный.

**ЦЕЛОВА'ЛЬНИК** *м. истор. устар.*— 1. аракы сатучы, кабакчы; 2. (борынгы Мәскәү дәүләтендә) целовальник, салым җыючы.

**ЦЕЛОВА'ЛЬНЫЙ: целовальная запись** *истор.*— ант язмасы, ант кәгазе (әүвәлге Россиядә — тәре үбеп ант бирү турындагы язма).

**ЦЕЛОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. целовать, целоваться; 2. *старин.* ант итү, ант бирү; *привести к целованию* — ант иттерү.

**ЦЕЛОВА'ТЬ** *несов.*— үбү. ◇ **Целовать крест** *старин.*— ант итү, (тәре үбеп) ант бирү.

**ЦЕЛОВА'ТЬСЯ** *несов.*— үбешү.

**ЦЕЛОДНЕ'ВНЫЙ** *книж. редко* — көн буе (көнозын) дәвам иткән, көн буена сузылган; *целодневный шум и гам* — көн буе дәвам иткән шау-шу.

**ЦЕ'ЛОЕ** *ср. в знач. сущ.*— 1. бөтен, бер бөтен; 2. *мат.* бөтен сан.

**ЦЕЛОМУ'ДРЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— әхлакый сафлык, чисталык, пакьлек; гыйффәтлелек, тугрылык; әхлаклылык, гаепсезлек.

**ЦЕЛОМУ'ДРЕННЫЙ** *книж.*— әхлакый саф, пакь; әхлаклы, гыйффәтле, тугрылыклы; гөнаһсыз; *целомудренная девушка* — гыйффәтле кыз.

**ЦЕЛОМУ'ДРИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.*— (әхлакый яктан) үзен яхшы тоту; гыйффәт, сафлык, пакьлек; гөнаһсызлык.

**ЦЕ'ЛОСТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— бер бөтенлек; бөтенлелек; *целостность мировоззрения* — дөньяга карашның бер бөтенлеге (тәмам төгәлләнгән бер бөтен булуы); *национальная целостность* — милли бөтенлек.

**ЦЕ'ЛОСТНЫЙ** *книж.*— бөтен, бер бөтен булган.

**ЦЕ'ЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — бөтенлек, бөтен хәлдә (бөтен килеш) булу; ватылмаган (бозылмаган, зарарланмаган) булу; *сохранить что-нибудь в целости* — берәр нәрсәне бөтен килеш (исән-имин) саклап тоту. ◇ **В целости и сохранности** — барысы да үз урынында, барысы да исән (әйберләр).

**ЦЕ'ЛЫЙ** — 1. бөтен, бер бөтен, бөтен бер, тулы бер, төгәл бер; *целый хлеб* — бер бөтен икмәк; *целый стакан молока* — бер стакан тулы сөт; *целая дюжина* — тулы бер дюжина; *прошло целых десять дней* — төгәл ун көн үтте; 2. бик күп, бик зур, зур бер, әһәмиятле бер, бөтен бер; *обсуждался целый ряд проблем* — бик күп мәсьәләләр тикшерелде; 3. бөтен, исән, зыян-зарарсыз; бозылмаган, ватылмаган; *замени разбитый стакан целым* — ватык стаканны бөтенгә алмаштырып бир әле; 4. *в знач. сказ. только кр. формы* үз урынында, югалмаган, исән; *все вещи целы* — бер әйбер дә югалмаган, барысы да урынында (исән); 5. исән-сау, исән-имин, сау, сау-сәламәт; *возвратился цел и невредим* — исән-сау йөреп кайтты; *была бы голова цела* — баш(ың) исән булсын; 6. *мат.* к. целое 2. ◇ **Целый век** — гомер буе, бөтен гомере; *сам бредил целый век обедом или балом* (Грибоедов)— бөтен гомере баллар-мәҗлесләр белән саташып үтте. **Целый день** —(көннең) көн буе, көн буена, көн озын. **Целыми днями** (часами)— көннәр (сәгатьләр) буе; көннең көн буе, көн озын. **Целый год** — бер ел буе, бер ел буена. **Единое целое** *книж.*— бүленмәс (аерылгысыз, монолит) бер бөтен. **В общем и целом**—гомумән, гомумән алганда, гомумән-әйткәндә. **В целом** — гомумән, тулаем алганда; *в целом статья производит хорошее впечатление* — тулаем алганда, мәкалә яхшы тәэсир калдыра.

**ЦЕЛЬ** *ж.*— 1. *воен.* цель, мишень; 2. *устар.* мушка (винтовкада); 3. максат, морат; исәп, теләк; *наша конечная цель — коммунизм* — безнең соңгы максатыбыз — коммунизм; *достигнуть цели* — теләгенә ирешү (моратына җитү). ◇ **С целью** или **в целях** *чего-н.*— максаты белән, өчен, исәп тотып, күздә тотып..., дип; *поехать с целью осмотра местности* — урын белән танышу өчен китү. **Попасть в цель** — 1 тию, тидерү, тигезү; 2. *перен.* „авырткан“ җиренә тидерү, туры әйтү, шәп әйтү. **Бить мимо цели** — 1. тигезә (тидерә) алмау, тимәү; 2. *перен.* туры килмәү, үткен (тапкыр) сүз әйтә алмау.

**ЦЕЛЬНОМЕТАЛЛИ'ЧЕСКИЙ** *тех.*— тоташ металлдан эшләнгән; *цельнометаллические вагоны* — тоташ металлдан эшләнгән вагоннар.

**ЦЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — бөтенлек, бердәмлек, ныклык.

**ЦЕЛЬНОТЯ'НУТЫЙ** *тех.*—тоташ металл... (кисәкләрдән ябыштырып түгел); *цельнотянутые трубы* — тоташ металл трубалар.

**ЦЕ'ЛЬНЫЙ** — 1. бөтен, тоташ, бер кисәктән торган; *цельная мачта* — тоташ мачта (җыелма кисәкләрдән корылмаган); *цельный гранит* — бер бөтен кисәктән торган гранит таш; 2. *перен.* (*о человеке*) эчке каршылыксыз, икеләнүсез, катгый; нык; (*о теории*) бер бөтен, тулы бер; 3. (*о молоке*) аертылмаган, өсте (каймагы) алынмаган; 4. (*о винах*) натураль, куш(ыл)маган; 5. *простореч.* к. целый 1. 2, 3.

**ЦЕ'ЛЬСИЙ** *м. мн.* нет — Цельсий термометры (бозның эрү ноктасыннан суның кайнау ноктасына кадәр булган аралык 100 градуска бүленгән термометр).

**ЦЕМЕ'НТ** *м. тех.*— цемент(су белән катыштыргач таш кебек катучан измә хасил итә торган порошок хәлендәге төзү материалы).

**ЦЕМЕНТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — 1. *тех.* цементлау, цементлап ныгыту, цемент салу, цемент тутыру, цемент белән каплау; *цементация горных пород в шахтах* — шахталарда тау токымнарын цементлау; 2. *тех.* цементацияләү, цементация ясау, чыныктыру (йомшак тимер яки корычның өс йөзен углерод белән махсус эшкәртеп катыландыру); 3. *геол.* цементлану, цементлашу, цементланыш (тау токымнарының эрегән минераль матдәләр белән берегеп катуы).

**ЦЕМЕНТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.*— 1. цементлау, цементлаштыру, цементлап ныгыту, цемент тутыру (салу); 2. цементацияләү, цементация ясау, чыныктыру, катыландыру (тимер һәм корычны махсус эшкәртеп); 3. *перен.* ныгыту, бердәмләштерү; *коммунисты цементируют ряды нашей армии* — коммунистлар армиябезнең сафларын ныгыталар.

**ЦЕМЕНТИ'РОВАТЬСЯ** *тех. геол.*— 1. *сов.* и *несов.* цементлану, цементлашу, цементацияләнү, чыныгу (тимер, корыч); цементланып ныгу, берегеп кату (тау токымнары); 2. *несов. страд. тех.* цементланылу, цементлаштырылу, цемент белән ныгытылу, беркетелү; цемент салыну, цемент тутырылу; 3. *страд. тех.* (йомшак тимер яки корыч) цементацияләнелү, цементация ясалу, чыныктырылу, катыландырылу; 4. *страд. перен.* (мөнәсәбәтләр) ныгытылу, бердәмләштерелү.

**ЦЕМЕНТИРО'ВОЧНЫЙ** *тех.*— 1. цементация ясый торган, цементацияләү...-ы; *цементировочный агрегат* — цементацияләү агрегаты (корыч я тимерне чыныктыру өчен); 2. беректергеч,ябыштырып беркетүче; *цементировочный состав* — беректергеч катнашма (төзү материалларын бер берсенә ябыштырып катыра торган цемент измәсе һ. б. ш.).

**ЦЕМЕ'НТНИК** *м. спец.*— цементчы, цемент белгече, цемент промышленносте эшчесе.

**ЦЕМЕ'НТНЫЙ** — 1. цемент...-ы; цемент эшләп чыгару...-ы; *цементный завод* — цемент заводы; *цементная печь* — цемент миче (цемент эшләп чыгара торган мич); 2. цемент..., цементтан эшләнгән (ясалган, коелган); *цементное основание* — цемент нигез, цементтан коелган фундамент.

**ЦЕМЕНТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. тех.*— к. цементировать.

**ЦЕМЕНТОВА'ТЬСЯ** *сов.* и *несов.*— к. цементироваться.

**ЦЕНА'** *ж.*—1. бәя, хак, бәһа; *оптовые цены* — күпләп сату бәяләре; *рыночная цена* — базар бәясе; 2. бәя, түләү хакы; *цены за услуги понижены* — хезмәт күрсәткән өчен түләү хаклары киметелде (мәсәлән, гостиницаларда); 3. *только ед. перен.* әһәмият, роль, кадер, бәя; *знать цену ч му-н.*—(берәр нәрсәнең) кадерен белү; *знать себе цену* — үз кадереңне үзең белү; 4. мәгънә; кызык, ямь; *какова цена его уверениям?*— аның ышандыруларының ни мәгънәсе бар? ◇ **Красная цена** — к. красный. **Повыситься в цене** — бәясе күтәрелү, базары күтәрелү. **Не стоять за ценой** — бәясеннән тормау (вакланып, сатулашып тормау). **Ценою подешевле** — очсызрак итеп, арзангарак төшереп (алу). **Ценою упорного труда** — бик күп хезмәт куеп (түгеп, салып) **Ценой больших усилий** — бик нык тырышлыклар белән. **Ценой больших потерь** — бик зур югалтулар белән, бик зур югалтулар бәясенә. **Ценою** *чего-н.*— берәр нәрсә исәбенә; *ценою потери здоровья* — сәламәтлеген какшату исәбенә. **Ценою жизни** — җанын биреп (булса да). **Добиться любой ценою** — ничек кенә булса да ирешү. **В цене** — бик кыйбат, кыйммәтле, бәяле; кыйбат йөри, кыйбат бәяләнә, үтемле. **Цены нет** — 1. бик кыйммәт; 2. *перен.* тиңсез, бәяләп бетергесез, гаять зур әһәмияткә ия. **Грош цена** — бер тиен тормый, сукыр бер тиен, поты бер тиен (бик арзан яки әһәмиятсез).

**ЦЕНЗ** *м.*— ценз (1. *полит.* теге яки бу политик хокуклардан, бигрәк тә сайлау хокукларыннан, файдалануны чикли торган шартлар; *возрастной ценз* — яшь цензы, ягъни сайлау-сайлану хокукын яшь дәрәҗәсе белән чикләү; *имущественный ценз* — мал-мөлкәт цензы (капиталистик илләрдә); 2. *истор.* борынгы Римдә — сан алу, милекне язып алу; 3. *спец.* предприятиене теге яки бу разрядка кертү өчен кирәкле шартлар; 4. *экон.* Англиядә һәм АКШта переодик рәвештә хуҗалык-промышленность объектларының һәм халыкның санын алу).

**ЦЕ'НЗОВЫЙ** *спец.*— цензлы, ценз таләпләренә җавап бирә торган.

**ЦЕ'НЗОР** *м.*— цензор (1. *истор.* әүвәлге Рим дәүләтендә гражданнарның санын алу, мал-мөлкәтен билгеләү, салым җыю кебек эшләрне башкаручы һәм шулай ук халыкның әхлагын һәм политик ышанычлылыгын тикшерүче түрә; 2. матбугат һәм сәхнә әсәрләрен күзәтеп, тикшереп торучы, басарга яки сәхнәдә куярга рөхсәт бирүче).

**ЦЕ'НЗОРСКИЙ** — цензор(лык) ...-ы; *цензорские обязанности* — цензор эше, цензорлык вазифалары.

**ЦЕНЗУ'РА** *ж. мн.* нет — цензура (1. *истор.* борынгы Римдә цензорлык вазифасы; 2. матбугатны, сәхнә әсәрләрен дөньяга чыгудан элек карап, басарга яки сәхнәдә куярга рөхсәт бирү; 3. матбугатны тикшерү идарәсе, цензура идарәсе; 4. *полит. загр.* парламентның эчке тәртип-кагыйдәләрен бозган өчен депутатларга бирелә торган шелтә)

**ЦЕНЗУ'РНЫЙ** — 1. цензура ...-ы; *цензурная комиссия* — цензура комиссиясе; 2. (цензура тарафыннан) басарга рөхсәт ителгән, басарга яраклы, сәхнәдә куярга рөхсәт ителгән; 3. *перен. разг. шутл.* әдәпле, әхлаклы, әдәп-әхлак чикләреннән чыкмаган.

**ЦЕНЗУРОВА'ТЬ** *несов. разг.*— цензуралау, цензурадан үткәрү (мәсәлән, басыласы әсәрне карау, күзәтү).

**ЦЕНИ'ТЕЛЬ** *м.*— 1. бәяләүче, бәя бирүче, бәяли белүче, тәкъдир итүче, кадерен (кыйммәтен) белүче, әһәмиятен белүче, хөрмәт итүче; *строгие ценители* — бик таләпчән бәя бирүчеләр; *ценители его таланта* — аның талантын тәкъдир итүчеләр.

**ЦЕНИ'ТЬ** *несов.* —1. (*назначить цену, оценивать*) бәя бирү, бәһа (хак) кую; бәяләү, бәһалау; хакын билгеләү; 2. *простореч. (запрашивать)* артык кыйбат сорау, кыйммәт бәяләү, күп сорау; 3. кыйммәтен (кадерен, бәясен) белү; югары бәяләү, югары (өстен) кую; бәяли белү, хөрмәт итү; тәкъдир итү; *ценить дружбу* — дуслыкның кадерен белү; *ценить кадры* — кадрларны бәяли белү.

**ЦЕНИ'ТЬСЯ** *несов.*—1. бәяләнү, кыйммәт йөрү, кыйбатлы булу, кыйммәт хисаплану; *народные таланты высоко ценятся в нашей стране* — безнең илебездә халык талантларына югары бәя бирелә; *товар этот плохо ценится* — бу товар бик түбән бәяләнә (бик арзан йөри); 2. *страд.* хак бирелү, бәя куелу; тәкъдир ителү, хөрмәт ителү.

**ЦЕ'ННИК** *м. спец.*— бәяләр күрсәткече, бәяләр исемлеге (товар бәяләрен күрсәткән белешмәлек).

**ЦЕ'ННОСТНЫЙ** *экон.*— бәяләрдә, бәя(ләр) ягыннан, кыйммәт ягыннан; *выполнение плана в товарном и ценностном выражении* — планның товар күләме һәм кыйммәт ягыннан үтәлеше.

**ЦЕ'ННОСТЬ** *ж.*—1. *только ед.* бәя, бәһа, кыйммәт, хак; *определить ценность меха* — мехның бәясен билгеләү; *посылка с объявленной ценностью* — кыйммәте күрсәтелгән посылка; 2. *перен.* әһәмият, кыйммәт, файда; әһәмиятлелек, мөһимлек, файдалылык; *исследование представляет большую ценность* — бу тикшеренү эше гаять зур әһәмияткә ия; 3. (*ценный предмет*) кыйммәтле әйбер, затлы нәрсә; *хранение ценностей* — кыйммәтле әйберләрне саклау; 4. *перен.* байлык, хәзинә; *духовные ценности* — рухи байлыклар; *культурные ценности* — культура хәзинәләре; *материальные ценности* — материаль (матди) байлыклар.

**ЦЕ'ННЫЙ** —1. бәяле, кыйммәтле, бәясе куелган, кыйммәте (хакы) билгеләнгән, бәясе күрсәтелгән; *ценные бумаги* — кыйммәтле кәгазьләр (мәсәлән, акча, заём, вексель һ. б.); 2. кыйммәтле, кыйммәт бәяле, кыйбатлы, югары бәяле; *ценные вещи* — кыйммәтле әйберләр (алтын һ. б. ш. кебекләр); *ценный подарок* — кыйбатлы бүләк; 3. *перен.* бик әһәмиятле, мөһим, кирәкле, файдалы, кыйммәтле; *ценный работник* — кирәкле (кыйммәтле) хезмәткәр; *ценное открытие* — бик әһәмиятле ачыш.

**ЦЕНТ** *м.*— цент (АКШта, Голландиядә һ. б. кайбер илләрдә төп акча берәмлегенең йөздән бер өлешенә тигез булган вак акча).

**ЦЕНТА'ВР** *м.* — к. кентавр.

**ЦЕ'НТНЕР** *м.* — центнер (1. тоннаның $^1/_{10}$ өлешенә яки 100 килограммга тигез булган авырлык үлчәве; 2. Англия, Германия, Швейцария һәм Даниядә 50 килограмм бәрабәрендә йөртелә).

**ЦЕНТР** *м.* — 1. *мат. мех.* үзәк, үзәк нокта; 2. урта, урталык, үзәк; урта өлеше, нәкъ уртасы; *жить в центре города* — шәһәрнең үзәгендә, уртасында яшәү; 3. *перен.* үзәк, иң әһәмиятлесе, иң мөһиме; *центр внимания* — игътибар үзәге; *Советский Союз— центр движения борьбы за мир* — Советлар Союзы тынычлык өчен көрәш хәрәкәтенең үзәге; 4. үзәк, үзәк шәһәр, баш шәһәр; *промышленный центр* — промышленность үзәге; 5. үзәк, үзәк оешма, үзәктәге җитәкче орган; *комиссия из центра* — үзәктән килгән комиссия; *директивы центра* — үзәктән килгән күрсәтмәләр; 6. *полит.* аралык (урталык) партияләр; *партии центра* — урталык партияләр, аралык партияләр (буржуаз парламентта гадәттә уң партияләргә якын торган аерым төркемнәр яки вак партияләр); 7. *чаще мн. тех.* үзәк күчәр (эшкәртелмә детальне урнаштыра торган очлы күчәр).

**ЦЕНТРА'Л** *м. дореволю.* — централ, үзәк төрмә (иске Россиядә барыннан да бигрәк политкаторжаннар тотыла торган каторга төрмәсе).

**ЦЕНТРАЛИЗА'ЦИЯ** *ж.* — 1. үзәкләштерү (дәүләт, идарә эшләрен бер үзәккә туплау); 2. к. централизовать, централизоваться.

**ЦЕНТРАЛИ'ЗМ** *м.* — централизм, үзәкләштерү системасы (җирле оешма-идарәләрнең үзәктәгеләргә буйсынып, аларның күрсәтмәләре белән эш итүе).

**ЦЕНТРАЛИЗО'ВАННЫЙ**—үзәкләштерелгән, бер үзәккә буйсынган; *централизованное снабжение* — үзәкләштерелгән тәэминат.

**ЦЕНТРАЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — үзәкләштерү, бер үзәккә туплау, бер үзәккә буйсындыру.

**ЦЕНТРАЛИЗОВА'ТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов.* үзәкләшү, үзәкләшкән булу; 2. *несов. страд.* үзәкләштерелү; бер үзәккә туплану, буйсындырылу (идарә, җитәкчелек).

**ЦЕНТРА'ЛКА** *ж. разг.* — 1. к. централ; 2. централка, централка мылтык (турыдантуры көпшәдән корыла торган затворсыз ау мылтыгы).

**ЦЕНТРА'ЛЬ** *ж.* — үзәк магистраль, үзәк линия.

**ЦЕНТРА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. үзәк булу, үзәк булганлык, үзәк булучылык; 2. әһәмиятлелек, мөһимлек; төп (үзәк) мәсьәлә булу.

**ЦЕНТРА'ЛЬНЫЙ**—1. үзәк, үзәктәге, уртадагы, урталыктагы; үзәктә торган; *центральные улицы* — үзәк урамнар; *занимать центральное положение* — үзәк урын алып (урталыкта) тору; 2. үзәк, җитәкчелек итүче; *центральный комитет* — үзәк комитет;

3. *перен.* төп, нигез, үзәк, көн үзәгендәге, иң әһәмиятле, иң мөһим; *центральный вопрос* — үзәк мәсьәлә; *центральная фигура в обществе* — җәмгыятьтә төп фигура; *центральная задача* — иң әһәмиятле, иң мөһим бурыч. ◇ **Ружьё центрального боя** *охот.* — к. централка. **Центральное отопление** — үзәктән ягып җылыту (үзәкләштерелгән җылыту) системасы.

**ЦЕНТРИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — центризм, урталык (эшчеләр хәрәкәтендә оппортунизмның бер төре).

**ЦЕНТРИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — 1. (инструментны) үзәккә урнаштыру, кую, беркетү; үзәк ноктага утырту; үзәкләрен бер сызыкка урнаштыру, туры китерү; 2. *токарн.* (эшкәртелмә детальнең) үзәген әз генә кырдырып уеп алу (детальне әйләнмә валга, кучәргә җайлап кую өчен).

**ЦЕНТРИ'СТ** *м. полит.* — центрист, центризм тарафдары.

**ЦЕНТРИ'СТСКИЙ** *полит.* — центризмча, центристларча; *центристская точка зрения* — центристларча караш.

**ЦЕНТРИФУ'ГА** *ж. тех.* — центрифуга (1. *физ. тех.* катнаш матдәләрне үзәктән качу көче тәэсире белән состав өлешләренә аера торган җайланма; 2. *спец.* сөт аергыч, бал суырткыч һәм сөтнең майлылык дәрәҗәсен билгели торган һ. б. ш. кебек машина һәм аппаратларның гомуми атамасы).

**ЦЕНТРИФУГА'ЛЬНЫЙ** — к. центробежный.

**ЦЕНТРИФУГИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — (центрифуга белән матдәне) состав өлешләргә аеру, аерту.

**ЦЕНТРОБЕ'ЖКА** *ж. тех. разг.* — к. центрифуга.

**ЦЕНТРОБЕ'ЖНЫЙ** *спец.* — үзәктән качучы, үзәктән кача торган; үзәктән качу...-ы; *центробежная сила* (*мех.*) — үзәктән качу көче. ◇ **Центробежные нервы** *анат. физиол.* — үзәктән китүче нервлар, үзәктән чыгучы нервлар (үзәк нерв системасыннан тәэсир алып, аны сизү һәм хәрәкәт органнарына җиткерә торган нервлар).

**ЦЕНТРОВА'ЛЬНЫЙ** *тех.* — үзәк тишү...-ы; *центровальный станок* — үзәк тишү станогы (эшкәртелмә әйберне станокта урнаштыру өчен үзәк тишә торган кыру станогы).

**ЦЕНТРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — к. центрировать.

**ЦЕНТРОВО'Й** — үзәк ..., уртадагы, урталыктагы, үзәктәге, үзәктә торган; *центровые игроки* — үзәктәге уенчылар, урталыкта уйнаучылар (мәсәлән, футбол уенында).

**ЦЕНТРО'ВОЧНЫЙ** *тех.:* **центровочное углубление** — үзәк тишеме, үзәк уемы (детальне кыру станогында эшкәрткәндә, аны кучәргә кую өчен детальнең үзәгендә тишелгән конуссыман уелма).

**ЦЕНТРОСТРЕМИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — үзәккә омтылучы, үзәккә баручы, үзәккә хәрәкәт итүче; *центростремительная сила* (*физ.*) — үзәккә омтылучы көч; *центростремительные нервы* (*анат.*) — үзәккә баручы нервлар, үзәккә килүче нервлар (сизү һәм хәрәкәт органнарыннан тәэсир алып, аны үзәк нерв системасына тапшыручы нервлар).

**ЦЕНТРОФО'РВАРД** *м. спорт.* — үзәк һөҗүмче (футбол-хоккей уеннарында уртадагы уенчы).

**ЦЕНТУРИО'Н** *м. истор.* — центурия башлыгы, йөз башы.

**ЦЕНТУ'РИЯ** *ж. истор.* — центурия (1. *воен.* борынгы Рим дәүләтендә йөз кешедән гыйбарәт гаскәр бүлеге; 2. *полит.* халыкның милек цензы буенча бүленешендәге бер катлау, сословие).

**ЦЕП** *м.* — 1. *с.-х.* чабагач; 2. *мн. тех.* көре (туку станында буй җепләрнең тигезлеген саклау өчен кулланыла торган йомры агач яки бау).

**ЦЕПЕНЕ'ТЬ** *несов.* — 1. катып калу; *цепенеть от ужаса* — куркудан катып калу; *цепенеть от холода* — суыктан катып калу (туңу, күшегү); 2. (*становиться бесчувственным, не реагировать*) баш кату, катып калу, шашып калу, исәңкерәп калу, берни сизмәү.

**ЦЕПЁНКА** *ж. обл.* — к. цепня.

**ЦЕ'ПЕНЬ** *м. зоол.* — тасма суалчан.

**ЦЕ'ПКА** *ж.* — 1. *простореч.* нечкә чылбыр, кечкенә чылбыр; 2. *обл.* элгеч, чөй.

**ЦЕ'ПКИЙ** — 1. нык ябыша (тота, эләктерә) торган; каптыручан, эләктерүчән; 2. *спец.* (*вязкий*) ябышучан, берегүчән, үзле; 3. *перен. разг.* нык тора торган, үзенекен итә торган; *цепкий человек* — үзенекен итә торган кеше.

**ЦЕ'ПКО** *нареч.* — нык, ябышып, тешетырнагы белән; *цепко держаться за свои мнения* — үз фикерендә нык тору.

**ЦЕ'ПКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. нык ябышучанлык, нык каптыручан, эләктерүчән булу; 2. (*вязкость*) үзлелек, ябыштыручанлык, берекетрү сәләте; 3. *перен.* ныклык, нык торучанлык; *проявить большую цепкость* — ныклык күрсәтү.

**ЦЕПЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. *разг.* к. цепляться 1; 2. эләктерү, каптыру, эләктереп тарту (үзенә); *не все цепляй, что мимо плывёт* (*посл.*) — һәрбер нәрсәне үзеңә эләктереп алырга гына торма; 3. *простореч. неодобр.* (*нацеплять, надевать на себя*) теләсә нәрсә кию, (өстенә) ни туры килсә шуны элү, тагу.

**ЦЕПЛЯ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. ябышу, эләгү; *платье цепляется за ветки* — күлмәк агач ботакларына эләгә; *кошка цепляется когтями* — песи тырнаклары белән ябыша; 2. тотыну, асылыну; *ребёнок цепляется за шею матери* — бала анасының муенына асылына; 3. *перен. разг.* теш-тырнагы белән ябышу, ябышып яту; эләктереп алу, тотыну; *цепляться за какую-нибудь мысль* — берәр фикерне эләктереп алу; *цепляться за старые нормы* — иске нормаларга ябышып яту.

**ЦЕПНО'Й I** — чабагач ...-ы; *цепное било* — чабагач тәпәче.

**ЦЕПНО'Й II** —1. чылбыр...-ы; *цепное звено* — чылбыр буҗрасы; 2. *тех.* чылбырлы; *цепная передача* — чылбырлы тапшыргыч; *цепной мост* — чылбырлы күпер; 3. чылбырдагы; *цепная собака* — чылбырдагы эт, бәйдәге эт; 4. *зоол.* чылбырсыман (садә хайваннар); *цепные кораллы* — чылбырсыман мәрҗәннәр.

**ЦЕПНЯ'** *ж. обл.* — кое чиләге (коедан су алу өчен чылбырга бәйләнгән чиләк).

**ЦЕПО'ЧЕЧНЫЙ** *спец.* — сәгать чылбыры ...-ы; *цепочечное производство* — сәгать чылбыры эшләү (эшләп чыгару).

**ЦЕПО'ЧКА** *ж.* —1. (*для часов*) сәгать чылбыры; 2. *воен.* цепочка (бер-бер артлы тезелеп баручы сугышчылар төркеме).

**ЦЕПЬ** *ж.* — 1. чылбыр; *якорная цепь* — якорь чылбыры; *железная цепь* — тимер чылбыр; *собака на цепи* — чылбырдагы (бәйдәге) эт; 2. *только мн. перен.* богау, богау чылбыры; *цепи рабства* — коллык богаулары; 3. *перен.* тезмә, җыелма; *цепь событий* — вакыйгалар тезмәсе; 4. тезмә (таулар тезмәсе, тау сыртлары); 5. *воен.* цепь (бер-берсеннән билгеле бер ераклыкта урнашкан укчылар тезмәсе, сафы). ◇ **Цепь управления** *ж.-д.* — идарә чылбыры (бөтен поездның идарә итү системасын тоташтырган кабель). **Электрическая цепь** *физ. тех.* — электр чылбыры (ток чыганагы белән бергә бер йомык линия тәшкил итүче үткәргечләр тоташтырмасы). **Спустить с цепи** *перен.* — бәйдән ычкындыру (теләсә нишләргә ирек бирү, мөмкинлек бирү).

**ЦЕ'РБЕР** *м.* —1. цербер (борынгы грек мифологиясендә тәмуг капкасын саклаучы усал эт); 2. *перен. книж. неодобр.* явыз сакчы, усал ялчы; азатлыкны буучы, залим, „явыз эт".

**ЦЕРЕБРА'ЛЬНЫЙ** —1. *анат.* ми...-ы; *церебральная жидкость* — ми сыекчасы; 2. *лингв.* — церебраль, тел очын аңкауга тартып әйтелә торган; *церебральные согласные* — церебраль тартыклар (мәсәлән, „р" кебек тел очын аңкауга күтәрү белән ясала торган тартыклар).

**ЦЕРЕМОНИА'Л** *м. книж.* — церемониал, тантана тәртибе (берәр йоланы, тантананы үткәрү өчен рәсми кабул ителгән тәртип-кагыйдәләр); *церемониал приёма послов* — илчеләрне кабул итү тантанасының тәртибе.

**ЦЕРЕМОНИА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — тантаналы; *церемониальный марш* — тантаналы марш.

**ЦЕРЕМОНИЙМЕ'ЙСТЕР** *м. устар. доревол. загр.* — церемониймейстер, тантана түрәсе (патша сарайларындагы тантаналарның төгәл башкарылуына күзәтчелек итүче сарай түрәсе).

**ЦЕРЕМОНИЙМЕ'ЙСТЕРСКИЙ** *дореволю загр.* — церемониймейстерлык ...-ы; *церемониймейстерские обязанности* — церемониймейстерлык вазифалары.

**ЦЕРЕМО'НИТЬСЯ** *несов.* —1. тартыну, тәкәллефләнү; тартынып тору; *прошу не церемониться* — тәкәллефләнеп тормавыгызны үтенәм, тартынмавыгызны үтенәм; 2. назланып тору, төчеләнеп тору; йомшак эш итү, кыюсызлык күрсәтү; *не церемоньтесь с ним* — аның белән артык назланып тормагыз (йомшак эш итмәгез); *она любит церемониться* — ул бик төчеләнергә ярата.

**ЦЕРЕМО'НИЯ** *ж.* — 1. церемония, тантана, йола; *церемония встречи послов* — илчеләрне кабул итү тантанасы; *свадебная церемония* — туй йоласы, туй тантанасы; 2. *перен. разг. ирон.* мәшәкатьле эш, эчпошыргыч (озын-озакка сузылган) нәрсә; *покупка билета — скучная церемония* — билет сатып алу — бик мәшәкатьле эш; 3. тәкәллеф, тартыну; назлану, кыланыш, төчеләнү; *оставь свои церемонии* — назлануларыңны (кылану-тартынуларыңны) ташла әле; *говорить без церемоний* — тәкәллефсез генә сөйләү.

**ЦЕРЕМО'ННИК** *м.*, **ЦЕРЕМО'ННИЦА** *ж. разг. устар.* — тәкәллефле кеше; (артык) назланучан кеше, төчеләнүчән кеше, кыланчык кеше.

**ЦЕРЕМО'ННИЧАТЬ** *несов. разг.* — к. церемониться 1.

**ЦЕРЕМО'ННО** *нареч.* — тәкәллеф белән, әдәпле генә; *церемонно поклониться* — әдәпле генә баш ию, тәкәллеф белән баш ию.

**ЦЕРЕМО'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет —1. тәкәллефлелек, нәзакәтлелек, әдәплелек; 2. назлылык, назланучанлык.

**ЦЕРЕМО'ННЫЙ** — 1. тәкәллефле, нәзакәтле, бик әдәпле, илтифатлы; *церемонное обращение* — тәкәллефле мөгамәлә; 2. (*жеманный*) назлы, назланучан, төчеләнүчән, кыланчык, кыстатучан; *церемонный гость* — назлы кунак, назланучан кунак.

**ЦЕ'РИК** *м.* — к. цирик.

**ЦЕРКВЁНКА, ЦЕРКВУ'ШКА** *ж. разг.* — кечкенә чиркәү.

**ЦЕРКО'ВНИК** *м.* —1. к. церковнослужитель; 2. чиркәүгә йөрүче, динче, дин тотучы, дингә ышанучы, диндар.

**ЦЕРКО'ВНИЦА** *ж.* —1. *устар.* чиркәү хезмәтчесе хатыны; 2 чиркәүгә йөрүче хатын, дин тотучы, диндар хатын.

**ЦЕРКОВНОПРИХО'ДСКИЙ** *дореол.* — чиркәү карамагындагы; *церковноприходская школа* — чиркәү карамагындагы мәктәп (чиркәү-мәхәллә мәктәбе).

**ЦЕРКОВНОСЛАВЯ'НСКИЙ** — чиркәү-славян ...-ы; *церковнославянский язык* — чиркәү-славян теле (борынгы славян теле).

**ЦЕРКОВНОСЛУЖИ'ТЕЛЬ** *м. устар.* — 1. чиркәү хезмәтчесе; 2. рухани, чиркәү (дин) әһеле.

**ЦЕРКО'ВНОСТЬ** *ж. устар.* — 1. диндарлык, динчелек, дингә ышанганлык; 2. динирухани тормыш; дини йолалар-кагыйдәләр.

**ЦЕРКО'ВНЫЙ** — 1. чиркәү ...-ы; чиркәү карамагындагы, чиркәү каршындагы; *церковные школы* — чиркәү мәктәпләре, чиркәү каршындагы мәктәпләр; 2. чиркәүдәге.

чиркәүдә үткәрелә торган; *церковная служба* — чиркәүдәге гыйбадәт; 3. дини; *церковный праздник* — дини бәйрәм; 4. *устар.* диндар, динчел, тәкъва; *церковный человек* — диндар кеше.

**ЦЕ'РКОВЬ** *ж.*— 1. чиркәү; 2. дин, христиан дине; *православная церковь* — православие дине; 3. чиркәү житәкчелеге, чиркәү җитәкчеләре.

**ЦЕСАРЕ'ВИЧ** *м. доревол.*— тәхет варисы (патшаның үзеннән соң тәхеткә утырырга тиешле улы).

**ЦЕСАРЕ'ВНА** *ж.*— 1. патша кызы; 2. тәхет варисының хатыны.

**ЦЕСА'РКА** *ж.*— Мисыр тавыгы (Африка тавыгы).

**ЦЕХ** *м.*— цех (1. завод-фабриканың билгеле бер төр эшләнмәләр чыгара торган бүлеге һәм шул бүлек урнашкан бүлмә, бина, зал; *литейный цех* — кою цехы; *кузнечный цех* — тимерчелек цехы; 2. *истор.* феодализм чорында Көнбатыш Европада билгеле бер кәсептәш һөнәрчеләрнең сословие оешмасы).

**ЦЕХОВО'Й** — 1. цех...-ы; *цеховая администрация* — цех администрациясе; *цеховой комитет* — цех комитеты; 2. *перен. разг. неодобр.* цех(чы)лык...-ы; тар төркем...-ы; тар, йомык, чикләнгән; *цеховые интересы* — тар интереслар (аерым төркем интереслары).

**ЦЕХОВЩИ'НА** *ж. мн.* нет, *неодобр.*— цехчылык (тар төркемчелек, аерым төркем интересын гына күзәтү; тарлык, чикләнгәнлек, йомыклык).

**ЦЕЦЕ'** *ж. нескл.*— цеце (йокы авыруы таратучы агулы чебен; Африка чебене).

**ЦИА'Н** *м. мн.* нет, *хим.*— циан (азот белән углерод кушылмасыннан гыйбарәт төссез, агулы газ).

**ЦИА'НИСТЫЙ** *хим.*— цианлы, циан катышкан, составында циан булган; *цианистый калий* — цианлы калий.

**ЦИА'НОВЫЙ** *хим.*— циан...-ы; *циановая кислота* — циан кислотасы.

**ЦИАНО'З** *м. мед.*— к. синюха 3.

**ЦИ'БИК** *м. устар.*— чәй шыры, чәй әр җәсе.

**ЦИВИЛИЗА'ТОР** *м. ирон.*— цивилизатор, цивилизация урнаштыручы, мәдәният таратучы, культура кертүче (цивилизация кертәбез дигән булып, бәйле һәм колониаль илләрдә үзләренең империалистик тәртипләрен урнаштыручыларга карата әйтелә).

**ЦИВИЛИЗА'ТОРСКИЙ** *ирон.*— цивилизаторларча..., цивилизаторлык...-ы; *цивилизаторская миссия* — цивилизаторлык миссиясе.

**ЦИВИЛИЗА'ЦИЯ** *ж.*— цивилизация, мәдәният (теге яки бу иҗтимагый-экономик формация өчен хас иҗтимагый үсеш һәм материаль культура дәрәҗәсе — баскычы); *советский народ спас мировую цивилизацию от фашистов* — совет халкы бөтен дөнья мәдәниятен фашистлардан саклап алып калды.

**ЦИВИЛИЗО'ВАННЫЙ** — цивилизацияле, мәдәниятле, мәдәниләшкән; *цивилизованные народы* — цивилизацияле халыклар, мәдәниятле халыклар.

**ЦИВИЛИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— цивилизацияләштерү, мәдәниләштерү, цивилизация урнаштыру.

**ЦИВИЛИЗОВА'ТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов.* мәдәниләшү, цивилизациягә ирешү; 2. *несов. страд.* цивилизацияләштерелү, мәдәниләштерелү, цивилизация урнаштырылу.

**ЦИВИЛИ'СТ** *м. юр.*— цивилист, цивилистика белгече (гражданлык хокуклары буенча махсус белемле юрист).

**ЦИВИЛИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *юр.*— цивилистика (гражданлык хокуклары турындагы белем).

**ЦИВИ'ЛЬНЫЙ** *книж. устар.*— штатский, гражданнарча (хәрби-гаскәри түгел). ◇ **Цивильный лист** *полит.*— конституцияле монархия илләрендә патшага сарай чыгымнары өчен ел саен парламент тарафыннан бирелә торган акча.

**ЦИГА'РКА** *ж. разг.*— (махоркадан) төргән тәмәке.

**ЦИГЕ'ЙКА** *ж.*— цигейка (1. махсус эшкәртелгән кәҗә мехы; 2. шундый мехтан тегелгән тун).

**ЦИГЕ'ЙКОВЫЙ** — цигейка..., цигейкадан тегелгән; *цигейковая шуба* — цигейка тун, цигейкадан тегелгән тун.

**ЦИДУ'ЛКА** *ж. разг. фам.*— кечкенә хат, хат кисәге, сәлам хат.

**ЦИК** (центральный исполнительный комитет) *м.*— ҮБК (үзәк башкарма комитеты).

**ЦИКА'ДА** *ж. зоол.*— цикада (кыр чикерткәсенең бер төре, корткыч бөҗәк).

**ЦИКЛ** *м.*— цикл (1. берәр нәрсәнең билгеле бер вакыт эчендә үсеше төгәлләнә торган процесслар җыелмасы; *производственный цикл* — житештерү циклы, житештерү процессының чималдан әзер эшләнмәгә кадәр бер әйләнеп чыгуы; 2. нинди дә булса бер гомуми принцип буенча берләшкән фәннәр төркеме; *исторический цикл* — тарих фәннәре циклы; 3. *перен.* мәгълүм бер бөтен тәшкил иткән әйберләр җыелмасы, тезмәсе; *цикл стихотворений* — шигырьләр циклы).

**ЦИКЛАМЕ'Н** *м. бот.* — Альп миләүшәсе.

**ЦИКЛИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *лит.*— циклләш(тыр)у; бер циклга берләш(тер)ү, тупла(н)у; *циклизация русских былин* — рус халык былиналарының бер циклга берләшкән булуы (тупланган булуы).

**ЦИКЛИ'СТ** *м. устар.*— велосипедчы, самокатчы (самокатта йөрүче).

**ЦИКЛИ'ЧЕСКИЙ** — к. цикличный.

**ЦИКЛИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — циклылык, кабатланмалы (әйләнмәле), булу; цикллап эшләү.

**ЦИКЛИ'ЧНЫЙ** — циклы, цикллап (башкарыла торган); цикллап кабатлана торган; *цикличное движение* — циклы хәрәкәт (кабатланмалы хәрәкәт); *цикличная работа* — цикллап башкарыла торган эш.

**ЦИКЛОВА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *спец.*— эшне циклларга бүлү, циклы эш; цикллап эшләү.

**ЦИКЛОВО'Й** *спец.*—1. цикл...-ы; *цикловая форма* — цикл формасы; 2. к. цикличный.

**ЦИКЛО'ИДА** *ж. мат.*— циклоида (әйләнә туры сызык буенча тәгәрәгәндә, аның бер ноктасы сыза торган кәкре сызык).

**ЦИКЛОИДА'ЛЬНЫЙ** *мат.*— циклоидаль, циклоида рәвешендәге; *циклоидальная линия* — циклоидаль сызык.

**ЦИКЛО'Н** *м.*—1. *метеор.* циклон (атмосфераның аз басымлы өлкәсендә һаваның бөтерелмә хәрәкәте; һава халенең кинәт үзгәрүенә һәм зур явым-төшемнәргә китерә); 2. *разг.* көчле җил, каты давыл, өермә; 3. *тех.* циклон, тузан суыргыч.

**ЦИКЛОНИ'ЧЕСКИЙ** — циклон...-ы; циклоник, циклонга хас; *циклонические вихри* — циклоник өермәләр; *циклонические явления* — циклон күренешләре.

**ЦИКЛО'П** *м.*—1. *миф.* циклоп (борынгы грек әкиятләрендә маңгай уртасында бер күзле гаять зур дию, алып); 2. *зоол.* циклоп, сыңаркүз (кыслачык).

**ЦИКЛОПИ'ЧЕСКИЙ** *истор.*— гаять зур, биек, гигант, алыптай (күбрәк борынгы корылмалар турында әйтелә).

**ЦИКЛОТРО'Н** *м. спец.*— циклотрон (атом төшен таркатканда электр корылмалы кисәкчәләрнең хәрәкәтен тизләтү аппараты).

**ЦИ'КЛЯ** *ж. столяр.*— цикля, кыргыч (ышкылган тактаның йөзен тигезләү һәм шомарту өчен кулланыла торган корыч пластинка).

**ЦИКО'РИЙ** *м. мн.* нет — һиндыба, цикорий (тамыры кофега кушу өчен кулланыла торган үсемлек).

**ЦИКО'РНИК** *м.*— к. цикорий.

**ЦИКО'РНЫЙ** —1. һиндыба тамыры...; *цикорное производство* — һиндыба тамыры җитештерү; 2. һиндыбадан хәзерләнгән; цикорий кушылган; цикорий...-ы; *цикорный кофе* — цикорий кофесе.

**ЦИКУ'ТА** *ж. бот.*—түндербаш, су балтырганы (зонт чәчәклеләр семьялыгыннан агулы үсемлек).

**ЦИЛИ'НДР** *м.*— цилиндр (1. *мат.* турыпочмаклыкны, бер кырын күчәр итеп алып, әйләндерүдән килеп чыккан геометрик җисем; 2. *тех.* эчке янулы двигательләрдә пешкәк йөри торган трубасыман куышлык; 3. цилиндр формасындагы биек, каты, тар кырыйлы эшләпә).

**ЦИЛИНДРИ'ЧЕСКИЙ** — цилиндрик, цилиндрсыман, цилиндр рәвешле, цилиндр формасындагы; *цилиндрический котёл* — цилиндрсыман казан, цилиндрик казан.

**ЦИЛИ'НДРОВЫЙ** *тех.*— цилиндр...-ы; цилиндр ясый торган; *цилиндровый чугун* — цилиндр чуены, цилиндрлык чуен (цилиндрлар коюга китә торган яхшы сыйфатлы чуен).

**ЦИМБАЛИ'Н** *м.*— цимбалин (төрле зурлыктагы пыяла стаканчыклардан төзеп ясалган уен коралы).

**ЦИМБАЛИ'СТ** *м. спец.*— цимбалчы, цимбал уйнаучы (музыкант).

**ЦИМБА'ЛЫ** *ед.* нет — цимбал (кечкенә чүкеч белән сугып уйнала торган кыллы музыка коралы).

**ЦИМЛЯ'НСКОЕ** *ср. мн.* нет — цимлян шәрабе (виноград аракысының бер төре).

**ЦИНГА'** *ж.*— зәңгелә, зәңгелә авыруы (витамин җитмәү аркасында теш уртларының бозылуы).

**ЦИНГО'ТЕТЬ** *несов. простореч.*— зәңгелә белән авыру, зәңгелә белән авырып яту.

**ЦИНГО'ТНЫЙ** — 1. зәңгелә...-ы; зәңгелә авырулы, зәңгеләле; *цинготные десны* — зәңгеләле уртлар; *цинготные признаки* — зәңгелә галәмәтләре; 2. зәңгелә белән авыручы; *цинготные больные* — зәңгелә белән авыручылар, зәңгеләле авырулар; 3. зәңгелә белән авыручылар...-ы; зәңгеләле авырулар...-ы; *цинготный барак* — зәңгеләле авырулар барагы; 4. зәңгелә...-ы, зәңгеләдән дәва булган; *цинготная трава* — зәңгелә үләне (зәңгеләне дәвалый торган үлән).

**ЦИНЕРА'РИЯ** *ж. бот.*— гөлчәчәк (катмар чәчәклеләр семьялыгыннан төрле төсле чәчәк ата торган декоратив үсемлек).

**ЦИНИ'ЗМ** *м.*—1. *истор. филос.* цинизм, цинизм тәгълиматы (борынгы Грециядә хөкем сөргән әхлак-әдәп нормаларын кире кагып, үз-үзеңне тотуда гадилекне, „табигатькә кире кайту"ны алга сөргән философик тәгълимат); 2. *перен.* оятсызлык, әдәпсезлек, әхлаксызлык; тупаслык, кабахәтлек, циниклык (культура һәм әхлак кагыйдәләренә игътибарсызлык).

**ЦИ'НИК** *м.*—1. *филос. истор.* цинизм тарафдары (борынгы Грециядә); 2. *перен.* оятсыз, әдәпсез, әхлаксыз; циник, затсыз; әшәке телле (сүзле).

**ЦИНИ'ЧЕСКИЙ** —1. *истор. фил.* цинизм...-ы; циниклар...-ы; *циническая школа* — циниклар мәктәбе (борынгы грекларда хөкем сөргән әхлакны кире кагып, табигый халәткә кире кайтуны яклый торган фәлсәфи мәктәп); 2. к. циничный.

**ЦИНИ'ЧНО** *нареч.*— оятсыз рәвештә; әшәке итеп, цинйкларча.

**ЦИНИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — оятсызлык, әдәпсезлек, циниклык; әшәке телле лек.

**ЦИНИ'ЧНЫЙ** — оятсыз, әдәпсез, әхлаксыз, әшәке телле, циник.

**ЦИНК** *м. мн.* нет — цинк (аксыл күк төсле металл; тутыя); *листовой цинк* — цинк калае.

**ЦИНКОВА'ТЬ** *несов. тех.*— цинклау, цинк белән каплау, тутыя йөгертү.

**ЦИНКОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. тех.*— цинклан(ыл)у, тутыя йөгертелү.

**ЦИ'НКОВЫЙ** — 1. цинк...-ы; цинк (тутыя) чыгара торган; *цинковый порошок* — цинк (тутыя) порошогы; *цинковая руда* — цинк рудасы; *цинковые разработки* — цинк чыгара торган шахта; 2. цинк(тан ясалган); *цинковое ведро* — цинк чиләк; 3. цинклы, тутыялы; *цинковая мазь* — цинклы мазь; *цинковый сплав* — цинклы коелма (эретмә).

**ЦИНКО'ГРАФ** *м. полигр.*— цинкограф, цинкография белгече.

**ЦИНКОГРА'ФИЯ** *ж. полигр.*— цинкография (1. *только ед.* фотография юлы белән цинк клишелар хәзерләү; 2. цинк тактага төрле рәсемнәр ясау сәнгате; 3. типогра-

фиядә цинк клишелар хәзерләү цехы, мастерское).

**ЦИ'ННИЯ** *ж. бот.*— цинния (кызыл чәчәкле декоратив үсемлек).

**ЦИНО'ВКА** *ж.*— чыпта, маты.

**ЦИНО'ВОЧНЫЙ** — 1. чыпта сугу...-ы; *циновочный станок* — чыпта сугу станогы; 2. чыпта...; чыптадан ясалган; *циновочная упаковка* — чыпта төргәк, чыптадан ясалган төрү материалы.

**ЦИНУ'БЕЛЬ** *м. столяр.*— тешле ышкы, сырлы ышкы, цинубель.

**ЦИ'РИК** *м.*— цирик (Монголия республикасы гаскәре сугышчысы).

**ЦИРК** *м.*—1. цирк; 2. цирк бинасы (түгәрәк тамаша заллы, ареналы һәм гөмбәзле махсус җиһазландырылган бина); 3. *геол.* (биек тау башында бозлыклар барлыкка килә торган) түгәрәк уйсулык.

**ЦИРКА'Ч** *м. разг.*— циркач, цирк артисты.

**ЦИРКА'ЧЕСКИЙ** *разг. неодобр.*—циркачлык ...-ы; циркачларча...; *циркаческие приёмы* — циркачлык алымнары.

**ЦИРКА'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. неодобр.*— циркачлык, шамакайлык (берәр эшне башкарганда циркка хас алымнар белән мавыгу).

**ЦИРКОВО'Й** — цирк...-ы; *цирковой артист* — цирк артисты; *цирковое здание* — цирк бинасы.

**ЦИРКУЛИ'РОВАТЬ** *несов.*—1. (туктаусыз) йөрү, әйләнеп йөрү, әйләнеп тору; *кровь циркулирует по телу человека* — кан кешенең тәне буенча туктаусыз әйләнеп йөри; 2. (хәбәр) таралу, йөрү, авыздан авызга сөйләнү; *в городе циркулируют слухи* — шәһәрдә хәбәрләр йөри; 3. *разг. фам.* арлы-бирле йөрү, йөреп тору.

**ЦИ'РКУЛЬ** *м.*— җәзбә, циркуль (әйләнә сызу өчен сызым коралы).

**ЦИ'РКУЛЬНЫЙ** —1. җәзбә (циркуль)...-ы; *циркульная ножка* — җәзбәнең бер очы; 2. әйләнә рәвешендәге, түгәрәк; 3. *архит.* гөмбәзсыман, көймәсыман, ярым түгәрәк.

**ЦИРКУЛЯ'Р** *м. офиц.*— циркуляр (югары оешмалардан түбән оешмаларга директив күрсәтмә-кулланма рәвешендә җибәрелгән рәсми кәгазь).

**ЦИРКУЛЯ'РНЫЙ** I *офиц.*— циркуляр...; циркуляр итеп җибәрелгән, кулланма (күрсәтмә, директива) итеп җибәрелгән; *циркулярное письмо* — циркуляр хат.

**ЦИРКУЛЯ'РНЫЙ** II *спец.*— түгәрәк, әйләнә формасындагы; *циркулярная пила* — түгәрәк пычкы.

**ЦИРКУЛЯЦИО'ННЫЙ** *спец.*— циркуляцион, циркуляция...-ы; *циркуляционные трубы* — циркуляция трубалары (су әйләнеп йөри торган трубалар).

**ЦИРКУЛЯ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — к. циркулировать.

**ЦИ'РЛИХ-МАНИ'РЛИХ** *м.* и *ж. разг. фам.* — назлы, кыланчык, ясалма манерлы.

**ЦИРРО'З** *м. мед.:* **цирроз печени** — бавыр циррозы, бавыр кабыклануы (яңа тукыма үсү сәбәпле иске тукыманың корып кабыкка әйләнүе; шуның нәтиҗәсендә сары авыруы булучан).

**ЦИРЦЕ'Я** *ж. миф.*— цирцея, сусылу (борынгы грек мифларындагы сихерче хатынкыз).

**ЦИРЮ'ЛЬНИК** *м. устар.*— чәч алучы, сакал - мыек кыручы, чәчтараш.

**ЦИРЮ'ЛЬНЯ** *ж. устар.*— к. парикмахерская.

**ЦИ'СТА** *ж. биол.*— тышкы кабык, тышча (кайбер садә организмнарда тышкы тәэсирдән саклану тышчасы).

**ЦИСТЕ'РНА** *ж.*— цистерна (1. сыекча яки газлар саклау өчен зур металл савыт; 2. җиргә казылып, төбе һәм стеналары су үткәрми торган итеп бетонланган сусаклагыч; 3. сыек ягулык һ. б. сыекчалар ташу өчен махсус җайланган вагон яки автомобиль).

**ЦИСТИ'Т** *м. мед.*— цистит (сидек куыгының ялкынсынуы, шешүе).

**ЦИТАДЕ'ЛЬ** *ж. мн.* нет — 1. *воен. истор.* цитадель, ныгытма (шәһәр эчендәге крепость); 2. *перен. книж. (оплот)* терәк, нигез, таяныч.

**ЦИТА'ТА** *ж.*— өземтә, өзек, цитата (берәр нәрсәне дәлилләү, нигезләү өчен берәр әсәрдән алынып авторның сүзләрен үзгәртмичә китерелгән текст.)

**ЦИТА'ТНЫЙ** — цитата...-ы; *цитатный материал* — цитата материалы (өземтәләр).

**ЦИТА'ЦИЯ** *ж. книж.*— 1. *только ед.* к. цитировать; 2. *только мн.* цитаталар, өземтәләр.

**ЦИТВА'РНЫЙ: цитварное семя** — дәрмана, дәрмана орлыгы; **цитварное масло** — дәрмана мае; **цитварная полынь** *бот.*— дәрмана, дәрмана үләне.

**ЦИТИ'РОВАННЫЙ** — цитата итеп китерелгән, өземтә итеп алынган.

**ЦИТИ'РОВАТЬ** *несов.*— цитата китерү, өземтә китерү, өзек алу; *цитировать классиков* — классиклардан өземтә китерү.

**ЦИТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— цитата (өземтә) итеп китерелү.

**ЦИТОВА'ТЬ (СЯ)** *несов. редко* — к. цитировать(ся).

**ЦИТОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *биол.*— цитологик, цитология буенча; *цитологические исследования* —цитология буенча тикшеренүләр.

**ЦИТОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *биол.*— цитология (биологиянең күзәнәк төзелеше, аның үзлекләре һәм яшәеше турындагы бер бүлеге).

**ЦИ'ТРА** *ж. муз.*— цитра (кыллы музыка коралының бер төре).

**ЦИТРОВАНИЛИ'Н** *м. мед.*— цитрованилин (баш авырткангa бирелә торган дару).

**ЦИТРОВАНИ'ЛЬ** *ж.*— к. цитрованилин.

**ЦИ'ТРУС** *м. бот.*— к. цитрусовые.

**ЦИ'ТРУСОВЫЕ** *в знач. сущ. ед.* нет, *бот.*— цитруслар, цитрус үсемлекләр (эссе якларда үсә торган җимеш агачларыннан бер төркем, мәсәлән, лимон, әфлисун, мандарин агачлары).

**ЦИ'ТРУСОВЫЙ** *бот.*— цитрус...; *цитрусовые плоды* — цитрус җимешләр (лимон, әфлисун һ. б.).

**ЦИФЕРБЛА'Т** *м.*— циферблат (1. сәгать битлеге; 2. үлчәгеч приборларда цифрлар сугылган түгәрәк).

**ЦИФЕРБЛА'ТНЫЙ** — 1. циферблат...-ы; *циферблатный круг* — циферблат түгәрәге; 2. циферблатлы; *циферблатные весы* — циферблатлы үлчәү.

**ЦИФИ'РЬ** *ж. мн.* нет, *устар.*— 1. *собир.* цифрлар, саннар; 2. хисап; хисаплау, санау, чутлау, исәпләү; 3. арифметика, хисап гыйлеме.

**ЦИ'ФРА** *ж.*— 1. цифр, (сан билгесе); *арабские цифры* — гарәп цифрлары; *римские цифры* — рим цифрлары; 2. *разг.* сан, сумма; *контрольные цифры* — контроль саннар; *назвать круглую цифру* — түгәрәк суммасын әйтү.

**ЦИФРА'ЦИЯ** *ж. спец.*— к. цифровать.

**ЦИФРОВА'ТЬ** *несов. спец.*— цифрлау, номерлау; сан куеп чыгу, цифр белән күрсәтү, сан белән билгеләү.

**ЦИФРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— цифрланылу, цифр белән күрсәтелү.

**ЦИФРОВО'Й** — 1. цифр(лар)...-ы; *цифровая система* — цифрлар системасы; 2. цифрлы, санлы; цифрлар белән билгеләнгән, саннар белән күрсәтелгән; *цифровое выражение* — сан белән күрсәтү; *цифровые данные* — санлы мәгълүматлар.

**ЦИ'ЦЕРО** *м. нескл. тип.*— цицеро (12 пункт зурлыгындагы типография шрифты).

**ЦК** (Центральный Комитет) *м.*— ҮК (Үзәк Комитет).

**ЦОК** *в знач. сказ. разг.*— чык (шак) итте; *пуля цок о камень* — пуля чык итеп ташка тиде.

**ЦО'КАЛЬЩИК** *м.*— цылаштыручы, цылаштырып сөйләүче („ч“ авазы урынына „ц“ әйтүче).

**ЦО'КАНЬЕ** I *ср. мн.* нет, *лингв.*— к. цокать 1.

**ЦО'КАНЬЕ** II *ср. мн.* нет — чыкылдау, шакылдау; чак-чок итү; *цоканье пуль* — пулялар чыкылдавы.

**ЦО'КАТЬ** I *несов. лингв.*— цылаштыру („ч“ урынына „ц“ белән сөйләү, мәсәлән, „ачкыч“ урынына „ацкыц“ дип әйтү).

**ЦО'КАТЬ** II *несов.*— чакылдау, шакылдау, чак-чок килү (ат тоягы, пуля һ. б.).

**ЦО'КНУТЬ** *однокр.*— чык итү (мәсәлән, пуля ташка).

**ЦО'КОЛЬ** *м.*— цоколь (1. *архит.* таш стенаның тышка чыгыбрак торган, аскы нигез өлеше; 2. *тех.* электр лампочкасының патронга борып кертелә торган өлеше — сырлы калай кидерелгән төплеге).

**ЦО'КОЛЬНЫЙ** *архит.*— 1. цоколь...-ы; *цокольный камень* — цоколь ташы; 2. цоколь биеклегендәге; *цокольный этаж* — цоколь биеклегендәге этаж.

**ЦО'КОТ** *м. разг., мн.* нет — к. цоканье II.

**ЦОКОТА'ТЬ** *несов. разг.*— 1. *(производить цокот)* шакылдату, чыкылдату; топ-топ килү; 2. *перен. фам. (говорить быстро)* такылдау, тәтелдәү, чәтелдәү.

**ЦОП** *в знач. сказ. простореч.*— шап, хап; *цоп в солдаты жениха!* — кияү буласы егетне хап солдатка! (солдатка алдылар).

**ЦО'ПАТЬ** *несов. простореч.*— 1. (хап итеп) эләктерү, тоту; 2. шап итеп сугу, кундыру; 3. *(падать)* лап итеп егылу, лып итеп утыру, аву.

**ЦО'ПНУТЬ** *однокр. простореч.*— 1. хап иттерү, эләктереп алу; 2. шап итеп сугып җибәрү, сугып кую; 3. лап итеп авып төшү.

**ЦУГ** *м.*— очка җигү, очлап җигү, мичәүгә җигү (бер-бер артлы җигелгән ике яки өч пар ат).

**ЦУГОВО'Й** — 1. мичәү...-ы; *цуговая лошадь* — мичәү аты; 2. мичәүләп, очлап..., очка...; *цуговая запряжка* — мичәүләп җигү, очлап җигү.

**ЦУ'ГОМ** *нареч.*— 1. мичәүләп, очлап җигеп (ике-өч пар атны); 2. *перен. разг. фам.* артыннан калмыйча, төркем-төркем, бер-бер артлы, тезелешеп; *за ней кавалеры цугом ходили* — кавалерлар аның артыннан калмыйча йөриләр иде.

**ЦУГУ'НДЕР: на цугундер** (взять, тянуть) *разг.* — җавапка тарту, җәзага тарту.

**ЦУГЦВА'НГ** *м. шахм.*— цугцванг (шахмат уенында мәҗбүри, котылгысыз йөреш).

**ЦУК** *м. спорт.*— к. цукать 1.

**ЦУКА'Т** *м.*— цукат (1. җимеш шикәрләмәсе, шикәрле җимеш; 2. шикәрләнгән әфлисун, лимон кабыгы).

**ЦУКА'ТНЫЙ** — цукат...-ы; шикәрле җимештән ясалган; *цукатный торт* — цукат торты, шикәрле җимештән ясалган торт.

**ЦУКА'ТЬ** *несов.*— 1. *спорт.* йөгәнне кинәт тарту, нык тартып кую; йөгән тартып атны куу; 2. *перен. школьн. арго устар.*— мыскыллау, мыскыл итү, мәсхәрәләү.

**ЦЫГА'Н** *м.*, **ЦЫГА'НКА** *ж.*— чегән, чегән хатын-кызы.

**ЦЫГА'НЕ** и **ЦЫГА'НЫ** *мн.*— чегән халкы, чегәннәр.

**ЦЫГА'НСКИЙ** — чегән(нәр)...-ы; *цыганский язык* — чегән теле; *цыганский хор* — чегәннәр хоры.

**ЦЫ'КАТЬ** *несов. простореч.*— (тс! дип) җикеренү, өстенә кычкыру, кычкырып куркыту.

**ЦЫ'КНУТЬ** *однокр.*— к. цыкать.

**ЦЫМЛЯ'НСКОЕ** *ср.*— к. цимлянское.

**ЦЫ'ПКА** *ж. разг.*— 1. *обл.* тавык, чебеш; 2. *простореч. фам.* бәбкәм, сөеклем, акыллым.

**ЦЫ'ПКИ** *мн.* I — „чеби“, чебиләү, чеби чыгу (аяк-кулга).

**ЦЫ'ПКИ** *мн.* II — к. цыпочки.

**ЦЫПЛЁНОК** *м.* (*мн.* **цыплята**) — чеби, чебеш (тавык чебие).

**ЦЫПЛЯ'ТИНА** *ж. разг. мн.* нет — чебеш ите, чеби ите.

**ЦЫПЛЯ'ТНИК** *м.*— 1. *обл.* чебеш тибүче (кара тилгән яки карчыга); 2. *простореч. устар.* тавык-чебеш белән сату итүче.

**ЦЫПЛЯ'ТНИЦА** *ж. обл.*— тавык карагы, чебеш карагы (төлкегә карата әйтелә).

**ЦЫПЛЯ'ЧИЙ** — чеби(ләр)...-ы; чебеш(ләр)...-ы; *цыплячий корм* — чебеш азыгы, чебиләр җиме.

**ЦЫ'ПОЧКА** *ж.* — к. цыпка.

**ЦЫ'ПОЧКИ**: **на цыпочках** (ходить, стоять) — аяк очы белән генә (басып йөрү); бармак очында гына (басып тору).

**ЦЫ'ПУШКА** — к. цыпочка.

**ЦЫП-ЦЫП** — чеп-чеп, чеби-чеби (тавык-чебешләрне чакыру ымлыгы).

**ЦЫЦ** *межд. простореч.* — чү, тс, (эн)дәшмә, авызыңны ачма, тынынны чыгарма.

# Ч

**ЧАБА'Н** *м. с.-х.* — чабан, көтүче (күбрәк сарыклар көтүче).

**ЧАБА'НИТЬ** *несов. обл.* — чабанлык итү, көтүчелек итү, көтү көтү.

**ЧАБЁР, ЧАБРЕ'Ц, ЧЕБЁР** *м. мн.* нет, *бот.* — чабыр, чамбыр (иренчәчәклеләр семьялыгыннан бер үсемлек).

**ЧА'ВКАНЬЕ** *ср. мн.* нет — 1. к. чавкать; 2. чапылдату тавышы.

**ЧА'ВКАТЬ** *несов.* — авыз чапылдату, лачкылдату, лач-лач чәйнәү.

**ЧА'ВКНУТЬ** *сов. разг.* — авыз чапылдатып алу, авыз чапылдатып кую, авыз лачкылдатып алу, авыз лачкылдатып кую.

**ЧАД** *м. мн.* нет — 1. ис, сөрем, төтен (янып бетмәгән күмердән яки янып торган майлы әйбердән чыккан төтен); *угореть от чада* — сөремнән исерү, башка ис тию; *кухонный чад* — кухня исе, кухня сөреме; 2. *перен. книж.* сөрем, аңгы-миңгелек, исереклек; *в чаду страсти* — дәрт исереклегендә.

**ЧАДИ'ТЬ** *несов.* — төтәү, төтенләү, төтен чыгару, ис чыгару; *печь чадит* — мич төтенли (мич төтен кайтара).

**ЧА'ДНО** *в знач. сказ.* — төтен тулган, сөрем тулган, ис тулган; *в избе было чадно* — өйгә төтен тулган иде.

**ЧА'ДНЫЙ** — 1. төтенле, сөремле, төтен белән тулган, төтенли торган, сөремли торган; *чадная кухня* — төтенли торган кухня; 2. *перен. книж.* сөремле, бозык, гыйшгашрәтле, фахиш; *чадная жизнь* — сөремле тормыш, бозык тормыш, фахиш тормыш.

**ЧА'ДО** *ср. церк.-книж.* — 1. *устар., теперь шутл.* бала, сабый, малай яки кыз; *мать лелеяла и баловала его, как балуют единственное чадо* (Гончаров) — әнисе аны бердәнбер баланы иркәләгән кебек назлап үстерә һәм иркәли иде; 2. *книж. ритор. устар.* ул(ы, ым, ың), кыз(ы, ым, ың), бала(сы, м, ң); *хвала и честь тебе, свободы чадо!* (Пушкин) — дан һәм хөрмәт сиңа, азатлык улы!

**ЧАДОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж. устар., теперь шутл.* — үз балаларын яратучы; *чадолюбивый отец* — үз балаларын яратучы ата.

**ЧАДОЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар., теперь шутл.* — үз балаларына мәхәббәт, үз балаларын ярату.

**ЧАДОРО'ДИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — бала тудыру.

**ЧАДОРО'ДНЫЙ** *книж. устар.* — бала тудыруга сәләтле, балалы.

**ЧАДОРОЖДЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.* — к. чадородие.

**ЧАДОУБИ'ЙЦА** *м.* и *ж. книж. устар.* — к. детоубийца.

**ЧА'ДОЧКО** *ср. разг. фам. ирон. неодобр.* — 1. к. чадо 1; 2. иркә, иркәләп бозылган, холыксыз (бала яки кеше).

**ЧАДРА'** *ж.* — чадра, бөркәнчек (мөселман динендәге халыкларда хатын-кызларның сынын һәм битен каплап йөри торган япма, пәрәнҗә).

**ЧАЕВА'ТЬ** *несов. обл.* — чәйләп утыру, (тәмләп) чәй эчеп утыру.

**ЧАЁВНИК** *м. разг.* — чәй яратучы, чәй һәвәскәре, чәйхур.

**ЧАЁВНИЧАТЬ** *несов. разг. фам.* — к. чаевать.

**ЧАЕВЫ'Е** *ед.* нет — чәйлек, чәйлек акча (вак-төяк йомышларны үтәгән өчен бирелгән акча).

**ЧА'ЕМЫЙ** *книж. устар.* — көтеп алына торган, өмет ителә торган, көтелә торган, көтелгән; *чаемые перемены* — көтелә торган үзгәрешләр, көтелгән үзгәрешләр.

**ЧАЕОБРАБО'ТКА** *ж. мн.* нет, *спец.* — чәй эшкәртү.

**ЧАЕПИ'ЙЦА** *м.* и *ж. разг. шутл. редко* — чәй эчү белән мәшгуль кеше, чәй яратучы, чәйхур.

**ЧАЕПИ'ТИЕ** *ср. мн.* нет, *разг.* — чәй эчү; *заниматься чаепитием* — чәй эчү белән мәшгуль булу.

**ЧАЕРАЗВЕ'СОЧНЫЙ** *спец.* — чәй төрү...-ы, чәй үлчәп кую...-ы; *чаеразвесочное отделение* — чәй төрү бүлеге.

**ЧАЕТОРГО'ВЛЯ** *ж. мн.* нет, *торг.* — 1. чәй сәүдәсе, чәй белән сәүдә итү; 2. чәй белән сәүдә итә торган урын.

**ЧАЕТОРГО'ВЫЙ** *торг.* — чәй сәүдәсе...-ы, чәй белән сәүдә итү...-ы; *чаеторговые организации* — чәй белән сәүдә итү оешмалары.

**ЧА'ЕЧНЫЙ** *зоол.* — акчарлак...-ы; *чаечное яйцо* — акчарлак йомыркасы.

**ЧА'ИНКА** *ж. разг.* — чәй бөртеге; *на губе чаинка осталась* — иренгә чәй бөртеге ябышып калды.

**ЧАЙ** I *м.* — 1. чәй; 2. *только ед. (чаепитие)* чәй эчү, чәй; *во время чая* — чәй эч-

кәндә, чәй янында; *вечерний чай* — кичке чәй; 3. *(вечер, банкет)* банкет, чәй мәҗлесе, сый мәҗлесе; *устроить чай* — чәй мәҗлесе җыю. ◇ **Кирпичный чай** — такта чәй. **На чай** (давать, брать) — чәйлек, чәйлек акча (бирү, алу); к. чаевые. **На чашку чая** (пригласить, звать) *разг.* — чәйгә чакыру, чәй мәҗлесенә чакыру. **Чай да сахар** или **чай и сахар** *простореч. устар.* — чәй(ң, гез) тәмле булсын! чәйләр тәмле булсын!

**ЧАЙ** II *ввод. сл. простореч.* — *(пожалуй, повидимому, вероятно)* ...-дыр, ...-дыр бит, ...-дыр әле, ...-дыр ахрысы; *чай, ты сходил в магазин* — син кибеткә барып кайткансыңдыр бит; *опять, чай, что-нибудь натворил* — тагын нәрсә булса эшләп ташлагандыр, ахрысы (тагын нәрсә булса эшләп ташлагандыр әле).

**ЧА'ЙКА** *ж.* — акчарлак.

**ЧА'ЙКОВЫЕ** *ед.* нет, *зоол.* — акчарлакчалар.

**ЧА'ЙНАЯ** *ж.* — чәйханә.

**ЧА'ЙНИК** I *м.* — чәйнек.

**ЧА'ЙНИК** II *м. простореч. шутл.* — к. чаёвник.

**ЧА'ЙНИЦА** I *ж.* — чәй савыты, чәй тартмасы.

**ЧА'ЙНИЦА** II *ж. простореч. шутл.* — к. чайник II.

**ЧА'ЙНИЧАНЬЕ** *ср. мн.* нет, *разг. фам.* — *(чаепитие)* чәй эчеп утыру, чәйләп утыру, чәй эчү белән мәшгуль булу, өзлексез чәй эчү.

**ЧА'ЙНИЧАТЬ** *разг. фам.* — к. чаёвничать.

**ЧАЙНЫЙ** — чәй...-ы; *чайная плантация* — чәй плантациясе; *чайный стол* — чәй өстәле. ◇ **Чайное дерево** *бот.* — чәй агачы (аерым очракларда хуш ис өстәү өчен чәчәге чәйгә кушыла торган агач). **Чайная роза** *бот.* — гөлчәчәкнең бер төре.

**ЧАЙХАНА'** *ж.* — чәйханә.

**ЧАКО'НА** *ж. муз.* — чакона (бию характерындагы борынгы инструменталь пьеса).

**ЧАКРЫ'ЖИТЬ, ЧЕКРЫ'ЖИТЬ** *несов. обл.* — кисү, тураклау, ботарлау.

**ЧАКРЫ'ЖНИК** *м. мн.* нет, *обл.* — куаклыклар белән аралашкан вак (кечкенә) урман.

**ЧАЛ** *м. мор. ав.* — (пароходларны, баржаларны һ.б.) бәйләп куя торган аркан, чылбыр.

**ЧАЛДО'Н** *м. обл.* — чалдон, Себердә туып үскән рус кешесе.

**ЧА'ЛИТЬ** *несов. мор. ав.* — (пароходларны, баржаларны һ. б.) тарттырып кую, бәйләп кую; *чаль паром к пристани* — паромны пристаньга тарттырып куй.

**ЧА'ЛКА** I *ж. мор. ав.* — 1. *только ед.* (пароходларны, самолётларны һ. б.) тарттырып кую, бәйләп кую; 2. к. чал.

**ЧА'ЛКА** II *ж. обл.* — бурлы ат.

**ЧАЛМА'** *ж.* — чалма.

**ЧАЛМОНОС'НЫЙ** *книж. устар.* — чалмалы, чалма урап йөрүче, чалма ураган (кигән).

**ЧАЛОПЕ'ГИЙ** *спец.* — ала бурлы, ала-кола, бурлы-чуар (ат төсе).

**ЧА'ЛЫЙ** — бурлы (ат төсе).

**ЧА'ЛЬЩИК** *м. мор.* — (пароходларны, баржаларны һ. б.) бәйләп, тарттырып куючы матрос.

**ЧАН** *м.* — чан (зур кисмәк, зур металл савыт).

**ЧАНОВО'Й, ЧАНОВЩИ'К** *м. спец.* — чанда эшләүче эшче.

**ЧАПА'Н, ЧЕПА'Н** *м.* — чапан.

**ЧАПИ'ГИ** *ж. обл.* — сабан тоткасы.

**ЧАПРА'К, ЧАПРА'ЧНИК** *м.* — к. чепрак, чепрачник.

**ЧАПЫ'ГИ** — к. чапиги.

**ЧАПЫ'ЖНИК, ЧЕПЫ'ЖНИК** *м. мн.* нет, *обл.* — шырлык, куе куаклык.

**ЧА'РА** *ж. книж. устар. нар.-поэт.* — чәркә (шәраб, эчемлек салып эчәр өчен ясалган савыт, касә, стакан).

**ЧАРДА'Ш** *м.* — чардаш (1. венгр халкының милли биюе; 2. шул бию көенә язылган музыкаль әсәр).

**ЧА'РКА** *ж. нар.-поэт. устар.* — 1. к. чара; 2. бер чәркә эчемлек (аракы).

**ЧАРОВА'ТЬ** *несов.* — 1. *устар.* сихерләү, тылсымлау; 2. *книж.* үзенә җәлеп итү, ис китәрү, хәйран калдыру, бик нык тәэсир итү, күңелне биләп алу, сокландыру; *чаровать красотой* — матурлык белән үзенә җәлеп итү.

**ЧАРО'ВНИК** *м.*, **ЧАРОВНИ'ЦА** *ж. устар.* — 1. сихерче, тылсымчы; 2. *перен.* үзенә җәлеп итүче, күңелне биләп алучы, сокландыручы.

**ЧАРОДЕ'Й** *м.*, **ЧАРОДЕ'ЙКА** *ж. книж.* — к. чаровник.

**ЧАРОДЕ'ЙНЫЙ** *книж. поэт. устар.* — к. чародейственный.

**ЧАРОДЕ'ЙСКИЙ** *книж.* — сихри, тылсымлы, сихерле торган, тылсымлый торган; үзенә җәлеп итә торган, күңелне биләп ала торган; *чародейская сила* — сихри көч.

**ЧАРОДЕ'ЙСТВЕННЫЙ** *книж. устар.* — сихри, тылсымлы; сихри, тылсымлы көчкә ия булган; *чародейственное средство* — тылсымлы көчкә ия булган чара.

**ЧАРОДЕ'ЙСТВО** *ср. книж. устар.* — 1. *только ед.* сихер, сихерчелек; 2. к. чары 2.

**ЧАРОДЕ'ЙСТВОВАТЬ** *несов. книж. устар.* — сихерләү, сихерчелек итү.

**ЧАРО'К** *м. спец.* — кечкенә чар (шомартучы, ялтыратучы станок).

**ЧАРТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *истор.* — чартизм (Англиядә 1836—1848 елларда эшчеләр хәрәкәте).

**ЧАРТИ'СТ** *м. истор.* — чартист, чартизм хәрәкәтендә катнашучы, чартизм тарафдары.

**ЧАРТИ'СТСКИЙ** *истор.* — чартистлар ...-ы, чартизм ...-ы; чартистлык ...-ы; *чартистское движение* — чартистлар хәрәкәте.

**ЧАРУСА'** *ед.* нет, *обл.* — саздыклы алан.

**ЧАРУ'ЮЩИЙ** *книж.* — 1. *устар.* сихерләүче, тылсымлаучы; 2. сокландыргыч, үзенә җәлеп итүче, күңелне биләп алучы, искиткеч; *чарующий голос* — сокландыргыч тавыш.

**ЧА'РЫ** *ед.* нет, *книж. поэт.*— 1. сихер, әфсүн, тылсым; 2. *перен.* сокландыру (чанлык), күңелне биләп алу, үзенә җәлеп итү, сокландыргыч көч.

**ЧАС** *м.*— 1. бер сәгать (60 минутлык вакыт); *опоздать на час, на два часа* — бер сәгатькә, ике сәгатькә соңга калу; 2. вакыт, сәгать; *который час?*— сәгать ничә?; *часы приёма* — кабул итү вакытлары (сәгатьләре); *всему свой час* — һәрнәрсәнең үз вакыты бар. ◇ **Битый час** — к. битый. **Настал последний час** — соңгы сәгать сукты (ягъни үлем сәгате килеп җитте). **В добрый час** — хәерле сәгатьтә. **Адмиральский час** *шутл.*— ашау-эчү вакыты. **На час** *ирон.*— беразга, аз гына вакытка; *калиф на час* — бер сәгатьлек хәлифә. **Не по дням, а по часам** — көнләп түгел, сәгатьләп. **Неровен час** — әйтеп булмый, әллә нәрсә булып куюы ихтимал, белмәссең, нәрсә булыр. **С часу на час** — бик якын арада, тиз арада, менә хәзер, менә-менә (нәрсә булса булырга тиеш). **Час от часу** — сәгать саен, көннән-көн; *час от часу не легче* — көннән-көн авырая бара.

**ЧАСО'ВЕННЫЙ** *спец.*— часовня ...-ы; *часовенный свод* — часовня гөмбәзе.

**ЧАСО'ВНЯ** *ж.*— часовня, кечкенә чиркәү.

**ЧАСОВО'Й** I — 1. (бер) сәгатьлек ...; *часовая лекция* — бер сәгатьлек лекция; 2. сәгатьләп; *часовая оплата* — сәгатьләп түләү; 3. сәгать ...-ы; *часовой мастер* — сәгать остасы; *часовая стрелка* — сәгать стрелкасы; 4. (көндезге яки төнге) сәгать бердәге, (көндезге яки төнге) бер сәгатькә билгеләнгән; *уехать часовым поездом* — сәгать бердәге поезд белән китү.

**ЧАСОВО'Й** II *м.*— сакчы, часовой, сакта торучы, каравылда торучы.

**ЧАСОВЩИ'К** *м.*— 1. сәгать остасы, сәгатьче, сәгать төзәтүче; 2. *устар.* сәгать кибете тотучы, сәгатьче.

**ЧАСОВЩИ'ЧИЙ** *простореч.*— сәгатьче ...-ы; сәгать остасы ...-ы; сәгать төзәтүче ...-ы; *часовщичий инструмент* — сәгать төзәтүче инструменты.

**ЧАСО'К** *м. разг.*— бер генә сәгать, берәр сәгать; *зайти на часок* — берәр сәгатькә кереп чыгу.

**ЧА'СОМ** *нареч. простореч.*— 1. кайчак, кайвакыт, вакыты-вакыты белән; 2. *(случайно)* ...-дыр (бит),... икән; *нет ли у вас, часом, на рубль мелочи?*—сездә бер сумлык вак акча булмасмы икән? сездә бер сумлык вак булмастыр?

**ЧАСОСЛО'В** *м. церк.*— часослов, догалык, догалык китабы.

**ЧАСО'ЧЕК** *м.*— к. часок.

**ЧА'СТЕНЬКИЙ** *разг.*— к. частый.

**ЧАСТЕ'НЬКО** *нареч. разг. фам.*— еш кына, бик еш, әледән-әле; *к нам он захаживает частенько* — безгә ул еш кына (әледән-әле) кергәли.

**ЧАСТЁХОНЬКО** *нареч. простореч.*— к. частенько.

**ЧА'СТИК** *м.*— 1. *спец.* еш итеп үрелгән җылым, ятьмә; 2. *обл.* куе урман; 3. *обл.* к. частокол; 4. *спец.* частик, еш ятьмә белән тотылган балык, вак балык.

**ЧАСТИКО'ВЫЙ** *спец.*— 1. еш итеп үрелгән, кечкенә күзәнәкле; *частиковый невод* — кечкенә күзәнәкле ятьмә; 2. еш үрелгән җылым белән тотылган, еш ятьмә белән тотылган, еш үрелгән җылым белән тотыла торган; еш ятьмә белән тотыла торган; *частиковая рыба* — еш ятьмә белән тотылган балык, вак балык.

**ЧАСТИ'ТЬ** *несов.* — 1. ешлату, ашыгу, тизләтү (кирәгеннән артык); *не части, играй помедленнее* — ашыкма, әкренрәк уйна; 2. *простореч.* ешлау, еш килү, еш йөрү; *с некоторого времени он начал частить к нам* — билгеле вакыттан алып ул безгә бик еш йөри башлады.

**ЧАСТИ'ЦА** I *ж.*— кисәк, аерым кисәк, өлеш, бөртек, тамчы; *мельчайшая частица пыли* — тузан бөртеге; *частица таланта* — талант кисәге, кечкенә генә талант.

**ЧАСТИ'ЦА** II *ж. грам.*— кисәкчә.

**ЧАСТИ'ЧКА** *ж.*— к. частица I.

**ЧАСТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— өлешчәлек.

**ЧАСТИ'ЧНЫЙ** *книж.*— өлешчә, бераз, аз гына тулы булмаган, тулысы белән үтәлмәгән; *частичный успех* — өлешчә уңыш; *частичная мобилизация* — өлешчә мобилизация; *он частично прав* — ул бераз хаклы.

**ЧА'СТНИК** *м.*— хосусый сәүдәгәр, хосусый предприниматель.

**ЧАСТНОВЛАДЕ'ЛЬЧЕСКИЙ** *экон.*— хосусый милек иясе ...-ы; хосусый милекче ...-ы; *частновладельческое имущество* — хосусый милекче милке.

**ЧА'СТНОЕ** *ср. мат.*— бүленмә, өлеш (бер санны икенче санга бүлүдән килеп чыккан сан).

**ЧАСТНОПРАКТИКУ'ЮЩИЙ** *офиц.* — хосусый практика белән шөгыльләнүче; *частнопрактикующий врач* — хосусый практика белән шөгыльләнүче врач.

**ЧА'СТНОСТЬ** *ж. книж.*— 1. *только ед.* аерымлылык, аерылып тору, хосусыйлык; *частность случая* — очракның хосусыйлыгы, очракның (вакыйганың) аерылып торуы; 2. вак-төяк, деталь; *незначительная частность* — әһәмиятсез деталь, әһәмияткә ия булмаган деталь; *обращать внимание на частности* — вак-төякләргә игътибар итү. ◇ **В частности** — аерым алганда, атап әйткәндә, шул исәптән, хосусан; *деятельность многих великих людей, в частности Пушкина, была стеснена современными им общественными условиями* — бик күп бөек кешеләрнең эшчәнлеге, шул исәптән Пушкинның эшчәнлеге дә, шул замандагы иҗтимагый шартлар белән кысылган иде.

**ЧА'СТНЫЙ** *книж.*— 1. аерым, хосусый; *частный вывод* — аерым нәтиҗә; *частный капитал* — хосусый капитал; *частное лицо* — аерым шәхес; *частная служба* — хосусый хезмәт; 2. *книж.* сирәк, сирәк очрый торган, очраклы, аерым; *это частный случай* — бу — аерым очрак; *нельзя обобщать частное явление* — очраклы күренешне гомумиләштерергә ярамый; 3. шәхси; *част-*

*ная переписка* — шәхси язышу; *я к вам по частному делу* — мин сезгә шәхси эш белән. ◇ **Частное определение** *право* — аерым билгеләү, хосусый билгеләү, махсус билгеләү. **Частный пристав** *дореволь.* — шәһәрнең аерым өлешенә беркетелгән полиция чиновнигы. **Частный дом** *истор.* — полиция бүлеге, час.

**ЧАСТОКО'Л** *м.* — казык читән, утыртма читән; *сад огорожен частоколом* — бакча казык читән белән уратылып алынган.

**ЧА'СТОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — к. частота.

**ЧАСТОТА'** *ж.* — 1. *только ед.* ешлык; *частота случаев* — очракларның ешлыгы; *частота ритма* — ритм ешлыгы; 2. *мн. спец.* ешлыклар; *сравнительная таблица частот* — ешлыкларның чыгыштырма таблицасы.

**ЧАСТОТОМЕ'Р** *м. тех.* — частотомер, ешлык үлчәгеч (электр тогының ешлыгын үлчи торган прибор).

**ЧАСТУ'ШЕЧНИК** *м.*, **ЧАСТУ'ШЕЧНИЦА** *ж.* — такмакчы.

**ЧАСТУ'ШЕЧНЫЙ** *лит.* — такмак ...-ы; *частушечный стиль* — такмак стиле.

. **ЧАСТУ'ШКА** *ж. лит.* — такмак.

**ЧА'СТЫЙ** — 1. куе, еш, тоташ, тыгыз; *частый лес* — куе урман, тоташ урман; *деревья насажены часто* — агачлар еш утыртылганнар; *частый холст* — тыгыз киндер; *частый огонь* — тоташ ут; 2. янәшә; *частые звёзды* — янәшә йолдызлар; 3. эледәнэле, гел; *частые встречи* — эледән-эле очрашып торулар.

**ЧАСТЬ** *ж.* — 1. өлеш; *одна пятая часть* — (берәр нәрсәнең) биштән бер өлеше; *часть рукописи набрана* — кулъязманың бер өлеше җыелган; 2. кисәк; *части света* — дөнья кисәкләре; *роман в пяти частях с эпилогом* — эпилогтан һәм биш кисәктән торган роман; 3. часть, кисәк; *запасные части* — запас частьлар; *части машин* — машина частьлары, машина кисәкләре; 4. *воен.* часть; *воинские части* — хәрби частьлар; 5. *устар.* час, полиция бүлеге; *мы попали в облаву и ночевали в части* — без облавага эләктек тә полиция бүлегендә (часта) кундык; 6. *перен. только ед. устар.* өлеш, язмыш; *пусть много скорбей тебе пало на часть, ты делишь чужие печали* (Некрасов) — синең өлешеңә бик күп хәсрәт төшкән булса да, син башкалар кайгысын уртаклашасың; 7. *разг.* пай, өлеш; *быть в части с кем-н.* — берәр кеше белән пайда булу; 8. (берәр учреждениенең) бүлеге, (берәр идарәнең) аерым тармагы; *хозяйственная часть* — хуҗалык эшләре бүлеге. ◇ **Избрать благую часть** *книж.* — иң яхшы карар кабул итү. **По большей части** или **большей частью** — күп очракларда, гадәттә. **По части** (чего или какой) *разг.* — ...-дан,...өлкәсендә; *по части математики я слаб* — математикадан мин көчсез, математика өлкәсендә мин көчсез. **Рвать** или **разорвать на части** *разг. перен.* — к. разорвать. **Части речи** *грам.* — сүз төркемнәре.

**ЧА'СТЬЮ** *нареч.* — өлешчә генә, аз гына; *он только частью прав* — ул бары тик өлешчә генә хаклы.

**ЧАСЫ'** *только мн.* — сәгать; *стенные часы* — стена сәгате; *карманные часы* — кесә сәгате (куен сәгате); *часы с боем* — суга торган сәгать. ◇ **Стоять на часах** — каравылда тору. **Стать на часы** — каравылга басу.

**ЧАТЬ** *ввод. сл. обл.* — к. чай II.

**ЧА'УС** *м. мн.* нет — чаус, эре виноград төре.

**ЧА'ХЛИК** *м.* — 1. *бот.* мүк очлары; 2. *обл.* ябык кеше.

**ЧА'ХЛОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. сулганлык, корыганлык, кипкәнлек; 2. ябыклык, чирләшкәлек.

**ЧА'ХЛЫЙ** — 1. корып-кибеп баручы, зәгыйфь, кибеп баручы, сулган; *чахлое растение* — зәгыйфь үсемлек; 2. ябык, көчсез, зәгыйфь, авыручан, чирләүчән, чирләшкә, чирле; *чахлый ребёнок* — чирләүчән (чирләшкә) бала.

**ЧА'ХНУТЬ** *несов.* — 1. сулу, кору, кибү; *цветы чахнут* — чәчәкләр сула; 2. *перен.* зәгыйфьләнү, чиргә сабышу, кибү; *чахнуть от тоски* — кайгыдан чиргә сабышу, кайгыдан (сагыштан) кибү.

**ЧАХО'ТКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — чахотка, үпкә авыруы, үпкә туберкулёзы, ютәл, ютәл авыруы. ◇ **Карманная чахотка** *разг. шутл.* — кесә сызлау (акчасызлык).

**ЧАХО'ТОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. устар.* — 1. чахоткалылык, ютәллелек; 2. *перен.* игътибарга лаексызлык, әһәмиятсезлек.

**ЧАХО'ТОЧНЫЙ** *разг.* — 1. чахотка белән авыручы, чахоткалы, туберкулёз белән авыручы, ютәл авырулы, үпкә авырулы, туберкулёзлы; *чахоточный больной* — чахоткалы авыру, ютәл авырулы кеше; 2. чахотка ...-ы, туберкулёз ...-ы, ютәл авыруы ...-ы, үпкә авыруы ...-ы; *чахоточный румянец* — чахотка алсулыгы; 3. *книж. перен.* әһәмиятсез, игътибарга лаексыз, начар; *под стол подстилают чахоточный коврик* (Достоевский) — өстәл астына начар палас җәяләр.

**ЧА'ША** *ж.* — 1. *истор.* касә, тустыган; 2. *перен. шутл.* шәраб, эчемлек, кызыл аракы; шәраб эчү, кызыл аракы эчү; *явилась семья друзей и с ними неизбежная „чаша"* (Гончаров) — якын дуслар килде һәм алар белән котылгысыз шәраб та килде. ◇ **Пить горькую чашу** *перен.* — ачы кайгы кичерү, тирән кайгыга төшү. **Смертная чаша** *перен.* — үлем. **(Как) полная чаша** *перен.* — ашлы-сулы, мөшкәсе тулы (өйдә бетенесе бар, өйдә бернәрсәгә дә мохтаҗлык юк). **Рубить в чашу** — (бура бураганда) бүрәнәнең башын чокырлап ую.

**ЧАШЕВИ'ДНЫЙ** — касәгә охшаган.

**ЧАШЕЛИ'СТИК** *м. бот.* — касә яфракчыгы (үсемлектә).

**ЧА'ШЕЧКА** *ж.* — 1. кечкенә чашка, кечкенә чынаяк, кечкенә йомры; 2. *бот.* чәчәк касәсе.

**ЧА'ШЕЧНЫЙ** — касә ...-ы; чынаяк ...-ы; *чашечное производство* — чынаяк производствосы.

**ЧА'ШКА** *ж.* — 1. чашка, чынаяк, йомры; *фарфоровая чашка* — фарфор чынаяк; 2. тез капкачы; *ушибить чашку* — тез капкачын авырттыру; 3. үлчәү тәлинкәсе; 4. *плотн.* бүрәнә чокыры, бүрәнә ырмавы (бура бураганда).

**ЧА'ШНИК** *м. истор.* — чашник (1. Москва Русенда эчемлек подваллары белән идарә итүче сарай чиновнигы; 2. монастырьларда эчемлекләр һәм эчемлек подваллары белән идарә итүче монах).

**ЧА'ШНИЧАТЬ** *несов. устар. обл.* — сыйлану, эчү, кәефләнү.

**ЧА'ЩА** *ж.* — куе урман, куе куаклык, чытырманлык.

**ЧА'ЩЕ** — 1. куерак, ешрак, тыгызрак; *этот лес чаще* — бу урман куерак, бу урман ешрак; 2. күбрәк; *он играет чаще на скрипке* — ул күбрәк скрипкада уйный.

**ЧАЩО'БА** *ж. обл.* — к. чаща.

**ЧА'ЯНИЕ** *ср. книж.* — өмет, өмет итү, көтү, ният, хыял, ышаныч; *чаяния рабочего класса осуществились в СССР* — эшчеләр сыйныфының өметләре СССРда тормышка аштылар. ◇ **Паче чаяния** или **сверх чаяния** *книж. устар.* — көтмәгәндә, өмет итмәгәндә.

**ЧА'ЯТЕЛЬНО** *ввод. сл. книж. устар.* — мөгаен, ахыры, күрәсең.

**ЧА'ЯТЕЛЬНЫЙ** *книж. устар.* — өмет итеп торган, көтелә торган.

**ЧА'ЯТЬ** *несов. книж. устар. простореч.* — өмет итү, көтү, ышану, уйлау; *и как ты свой народ счастливым сделать чаешь?* (Крылов) — һәм ничек итеп син үз халкыңны бәхетле итәргә уйлыйсың? ◇ **Души не чаять** — к. душа. **Чающие движения воды** *книж. ирон.* — нәрсә дә булса көтеп торучылар, нинди дә булса уңайлылык (дәрәҗә, җылы урын) көтеп торучылар.

**ЧВА'НИТЬСЯ** *несов. разг.* — һавалану, мактану, масаю, мактанчыклану, тәкәбберләнү, кәпрәю, мин-минләнү.

**ЧВАНЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — һаваланучанлык, мактанучанлык, тәкәбберлек, мин-минлек.

**ЧВАНЛИ'ВЫЙ** *разг.* — һаваланучан, һаваланырга яратучан, мактанчыкланучан, мактанчыкланырга яратучы, тәкәбберләнүчән, тәкәбберләнергә яратучы.

**ЧВА'ННЫЙ** *разг.* — һавалы, тәкәббер, мактанчык, тәкәбберлек белән тулган; *чванный характер* — мактанчык характер.

**ЧВА'НСТВО** *ср. мн.* нет, *разг.* — һавалану, мактану, мактанчыклык, мин-минләнү, мин-минлек, буш куыклык.

**ЧЕБЁР** *м.* — к. чабёр.

**ЧЕБОТА'РИТЬ** *несов. разг.* — итек (башмак, кәвеш һ. б.) тегү, итек (башмак, кәвеш һ. б.) тегү белән шөгыльләнү.

**ЧЕБОТА'РЬ** *м. обл.* — итекче, башмакчы, кәвешче, итек (башмак, кәвеш) тегүче.

**ЧЕБРЕ'Ц** *м.* — к. чабёр.

**ЧЕБУРА'ХНУТЬ** *сов. простореч.* — китереп торып бәрү, дөберДәтеп бәрү, шалтыратып сугу, җимерү, шалтыратып төшерү.

**ЧЕБУРА'ХНУТЬСЯ** *сов. простореч.* — (идәнгә, җиргә, суга һ. б.) килеп төшү, шалтырап (дөбердәп) төшү, җимерелеп төшү, дөбер-шатыр аву, шап итеп барып төшү (егылу).

**ЧЕБУРЕ'К** *м. обл.* — чибәрәк, итле сумса.

**ЧЕГО'** *простореч.* — 1. *нареч. вопросит. обл.* — нигә, ник, нәрсәгә; *чего же так долго ездила?* — нигә соң болай озак йөрдең? *чего я туда пойду?* — нәрсәгә мин анда барыйм? 2. *междом.* әлбәттә, шулай түгелме әллә? (хәбәр ителә, сөйләнелә торган фикерне раслау мәгънәсендә).

**ЧЕГО'-ТО** *простореч.* — к. что-то II.

**ЧЕЙ** (чья, чьё, чьи) — кем, кемнең, кемнеке; *чья эта книга* — бу кем(нең) китабы?

**ЧЕК** *м. банк.* и *торг.* — чек; *получить деньги по чеку* — чек белән акча алу.

**ЧЕКА'** I *ж.* — чигә чөй (арбада), чикә (машиналарда), чәкүшкә; *болтовая чека* — болт чикәсе; *осевая чека* — күчәрнең чигә чөе.

**ЧЕКА'** II (чрезвычайная комиссия по борьбе с контрреволюцией, саботажем и спекуляцией) *ж. нескл. истор.* — чека (контрреволюциягә, саботажга һәм спекуляциягә каршы көрәшү өчен 1918 нче елда төзелгән гадәттән тыш комиссия).

**ЧЕКА'Н** *м. спец.* — 1. к. чеканить; 2. чекан (а. акчага, медальгә һ. б. ш. нәкышь төшерә торган штемпель; б. нәкышь, бизәк; *монеты одного чекана* — бер үк нәкышьле (бизәкле) акчалар; в. чүкү коралы; г. *истор.* бер ягы балта, икенче ягы чүкеч итеп ясалган корал).

**ЧЕКА'НИТЬ** *несов.* — 1. сугу; *чеканить монету* — акча сугу; *чеканить медали* — медальләр сугу; 2. (металл әйберләргә) бизәкләр төшерү; 3. *перен.* өздереп сөйләү, бик ачык итеп сурәтләү; 4. *спец.* чүкеп эшкәртү; *чеканить заклёпочные швы* — заклёпка җөйләрен чүкеп эшкәртү; 5. *с.-х.* кырку, кисү (өлгерүне тизләтү өчен үсемлекләрнең, җиләк-җимеш агачларының очтагы үсентеләрен кырку); *чеканить виноград* — виноградның очтагы үсентеләрен кырку.

**ЧЕКА'НИТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. сугылу (мәсәлән, акча); 2. бизәк төшерелү (берәр металл әйбергә).

**ЧЕКА'НКА** *ж. мн.* нет — 1. к. чеканить 1, 2, 4, 5; 2. нәкышь, бизәк (металл әйберләрдә); *ружьё с золотой чеканкой* — алтын бизәкле мылтык.

**ЧЕКА'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — яхшы эшкәртелгәнлек, чарлангалык; *чеканность стиля* — стильнең яхшы эшкәртелгәнлеге, чарланганлыгы.

**ЧЕКА'ННЫЙ** — 1. *спец.* бизәк төшерү ...-ы; нәкышь төшерү ...-ы, акча сугу ...-ы; *чеканный стан* — бизәк төшерү станы; 2. *перен. книж.* — чарланган, пөхтә эшкәртелгән, ачык, ачык эшләнгән, коеп куелган; *чеканный стиль* — чарланган стиль.

**ЧЕКА'НЩИК** *м. спец.* — акча сугучы. (металл әйберләргә) бизәк төшерүче, нәкышь төшерүче.

**ЧЕКИ'СТ** *м.*, **ЧЕКИ'СТКА** *ж.* — чекист (контрреволюциягә, саботажга һәм спекуляциягә каршы көрәш органында — Чекада эшләгән работник).

**ЧЕКМА'РЬ** *м. спец. обл.* — (кирпеч сукканда балчыкны төя торган) тукмак, төйгеч.

**ЧЕКМЕ'НЬ** *м.* — чикмән.

**ЧЕ'КОВЫЙ** — чек ...-ы; *чековая книжка* — чек кенәгәсе.

**ЧЕКОДА'ТЕЛЬ** *м. банк.* — чек бирүче.

**ЧЕКРЫ'ЖИТЬ, ЧЕКРЫ'ЖНИК** — к. чакрыжить, чакрыжник.

**ЧЕЛЕ'СТА** *ж. муз.* — челеста (металл пластинкалардан торган клавиатуралы музыкаль инструмент).

**ЧЁЛН** *м.* — каек, көймә.

**ЧЕЛНО'К** I *м.* — кечкенә көймә, бәләкәй каек.

**ЧЕЛНО'К** II *м.* — соса, суса (туку эшендә, тегү машинасында).

**ЧЕЛНО'ЧНИК** I *м. спец.* — каекчы, көймәче, каек (көймә) ясаучы.

**ЧЕЛНО'ЧНИК** II *м.* — соса остасы, суса ясаучы.

**ЧЕЛНО'ЧНЫЙ** I *спец.* — каек ...-ы, көймә ...-ы; *челночные приспособления* — каек жайланмалары.

**ЧЕЛНО'ЧНЫЙ** II *спец.* — соса ...-ы, суса ...-ы; *челночная катушка* — соса шүресе.

**ЧЕЛО'** *ср.* — 1. *только ед. устар. поэт. ритор.* — маңгай; 2. *обл.* мич авызы; 3. *спец.* ягулык ыргыту тишеге (металл эретә торган мичләрнең алгы як стенасында ягулык ыргыту өчен ясалган тишек). ◇ **Бить челом** — баширу (баш ору), аякка егылу, ялыну-ялвару.

**ЧЕЛОБИ'ТНАЯ** *ж. истор.* — үтенеч кәгазе, гариза (борынгы Русьта).

**ЧЕЛОБИ'ТЧИК** *м.*, **ЧЕЛОБИ'ТЧИЦА** *ж. истор.* — үтенеч кәгазе бирүче, үтенеч белән мөрәҗәгать итүче.

**ЧЕЛОБИ'ТЬЕ** *ср. истор.* — 1. баширу (баш ору), аякка егылу (борынгы Русьта); 2. үтенеч кәгазе тапширу; 3. үтенеч кәгазе, гариза.

**ЧЕЛОВЕ'К** *м.* — 1. кеше, адәм; *советский человек* — совет кешесе; *честный человек* — намуслы кеше; 2. ... кешелек, ... кешедән торган; *отряд в пятьдесят человек* — илле кешелек (илле кешедән торган) отряд; 3. *истор.* хезмәтче, ялчы кеше (крепостное право заманында алпавыт йортында); *к вам человек с докладом* (Грибоедов) — сезгә доклад белән хезмәтчегез килгән; 4. *дореводл.* официант, половой; *человек, рюмку водки!* — официант, бер рюмка аракы! ◇ **Божий человек** *устар. нар.-поэт* — алла бәндәсе, дивана. **Молодой человек** *разг.* — егет (яшь, үсмер кешегә мөрәҗәгать итү). **Свой человек, свои люди** — үз кеше, үз кешеләр, әшнәләр.

**ЧЕЛОВЕКОДЕ'НЬ** *м. экон.* — бер кешенең эш көне.

**ЧЕЛОВЕКОЛЮ'БЕЦ** *м. книж. устар.* — кеше сөючән (кеше), кеше яратучан (кеше), кешелекле кеше.

**ЧЕЛОВЕКОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж. устар.* — кеше сөючән, кеше яратучан, кешелекле.

**ЧЕЛОВЕКОЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — кеше сөючелек, кеше яратучылык, кешелеклелек; *проявить человеколюбие* — кешелеклелек күрсәтү.

**ЧЕЛОВЕКОНЕНАВИ'СТНИК** *м. книж.* — кеше сөймәүче, кеше күрә алмаучы, кешегә нәфрәт белән тулган, кешелекне сөймәүче, кешелекне күрә алмаучы, кешелеккә нәфрәт белән тулган.

**ЧЕЛОВЕКОНЕНАВИ'СТНИЧЕСКИЙ** — *книж.* — кешеләрне сөймәү ...-ы; кешеләргә нәфрәт ...-ы; кешелеккә нәфрәт ...-ы; *человеконенавистническая политика поджигателей войны* — сугыш уты кабызучыларның кешеләргә нәфрәт политикасы.

**ЧЕЛОВЕКОНЕНАВИ'СТНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.* — кешеләргә нәфрәт, кешеләрне сөймәү, кешеләрне күрә алмау, кешелеккә нәфрәт, кешелекне сөймәү, кешелекне күрә алмау.

**ЧЕЛОВЕКООБРА'ЗНЫЙ** *книж.* — кешегә охшаган, кешесыман; *человекообразная обезьяна* — кешесыман маймыл.

**ЧЕЛОВЕКОУБИ'ЙСТВО** *ср. книж. устар.* — кеше үтерү, кеше үтерүчелек.

**ЧЕЛОВЕКОУБИ'ЙЦА** *м.* и *ж. книж. устар.* — кеше үтерүче.

**ЧЕЛОВЕКОЧА'С** *м. экон.* — кешенең бер сәгатьлек эше.

**ЧЕЛОВЕ'ЧЕСКИЙ** — 1. кеше ...-ы; *человеческий организм* — кеше организмы; 2. кешегә хас, кешегә хас булган; *человеческие недостатки* — кешегә хас житешсезлекләр; 3. кешелекле, шәфкатьле, кешелек...-ы; *человеческое отношение* — кешелекле мөнәсәбәт, кешелек мөнәсәбәте.

**ЧЕЛОВЕ'ЧЕСТВЕННЫЙ** *книж. устар.* — к. человеческий.

**ЧЕЛОВЕ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — кешелек дөньясы, кешеләр.

**ЧЕЛОВЕ'ЧИЙ** *разг.* — кеше ...-ы; кешегә хас; *доносились человечьи голоса* (М. Горький) — кеше тавышлары ишетелә иде (сөйләшкән тавышлар ишетелә иде).

**ЧЕЛОВЕ'ЧИНА** *разг.* — 1. *м.* и *ж. фам.* дәү кеше; 2. *только ед. ж.* кеше мәете, кеше ите (ерткыч хайваннар өчен азык буларак); 3. *перен.* кеше эзе, кеше эзе калган урын, кеше булган урын, кеше торган урын.

**ЧЕЛОВЕ'ЧИШКО** *м. разг. фам. пренебр.* — кеше кисәге, бәндә, бәндә кисәге, адәм актыгы; *хоть и дрянной человечишко, но гостеприимен* (Чехов) — әшәке бәндә булса да, кунакчыл.

**ЧЕЛОВЕ'ЧИЩЕ** *м. разг.* — 1. дәү кеше, мәһабәт кеше; *экий человечище* — дәү дә кеше соң, мәһабәт тә кеше соң; 2. бөек кеше, олуг кеше; *он был не обыкновенный*

*человек, а человечище* — ул гади кеше түгел, олуг кеше иде.

**ЧЕЛОВЕ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — кешелеклелек, шәфкатьлелек; *в нем нет ни капли человечности* — анарда кешелеклелекнең әсәре дә юк.

**ЧЕЛОВЕ'ЧНЫЙ** — кешелекле, шәфкатьле; *человечное отношение* — шәфкатьле мөнәсәбәт.

**ЧЕ'ЛЮСТНЫЙ** *анат. мед.* — теш казнасы ...-ы, казналык ...-ы; *челюстная кость* — казналык сөяге; *челюстная операция* — теш казнасына операция ясау, казналыкка операция ясау; *челюстная хирургия* — теш казнасы хирургиясе (теш казнасын хирургия юлы белән дәвалау).

**ЧЕ'ЛЮСТЬ** *ж.* —1. теш казнасы; *нижняя челюсть* — аскы теш казнасы; *верхняя челюсть* — өске теш казнасы; 2. ясалма тешләр.

**ЧЕЛЯДИ'НЕЦ** *м.*, **ЧЕЛЯДИ'НКА** *ж. истор.* — ялчы, хезмәтче (алпавыт йортында).

**ЧЕ'ЛЯДЬ** *ж. мн.*, нет, *собир. истор.* — 1. ялчылар, хезмәткәрләр (алпавыт йортында); 2 *перен. презрит.* ялагайлар, ялагайланып ярарга тырышучылар.

**ЧЕМ** *союз* — 1. ... караганда; *эта комната лучше, чем ваша* — бу бүлмә сезнекенә караганда яхшырак; 2. *разг.* ...-ганчы, урынына, ...-га караганда; *чем торопиться, пойдём лучше раньше* — ашыкканчы, иртәрәк чыгуыбыз яхшырак; *чем бы помочь, он ещё мешает* — ярдәм итү урынына ул әле комачаулап тора; 3. ...-ган саен, күпме, никадәр; *чем больше, тем лучше* — никадәр күп булса, шулкадәр әйбәтрәк; *чем дальше, тем лучше* — ерагайган саен (еракарак киткән саен) әйбәтрәк. ◇ **Чем свет** — кара таңнан, таң тишегеннән, бик иртә.

**ЧЕМБУ'Р** *м.* — тезген.

**ЧЕМЕРИ'ЦА** *ж. мн.* нет, *бот.* — аксыргак.

**ЧЕМЕРИ'ЧНЫЙ** *бот.* — аксыргак ...-ы; *чемеричный корень* — аксыргак тамыры.

**ЧЕМОДА'Н** *м.* — 1. чемодан; 2 *перен. разг. шутл.* корсак, эч; *набить свой чемодан* — корсак тутыру (ашап-эчеп); 3. *разг. устар.* — эре калибрлы снаряд.

**ЧЕМОДА'ННЫЙ** — чемодан ...-ы; *чемоданный замок* — чемодан йозагы, чемодан биге.

**ЧЕМОДА'НЩИК** *м. спец.* — чемодан остасы, чемодан мастеры, чемодан ясаучы.

**ЧЕМПИО'Н** *м.* — 1. чемпион, көрәш батыры, (спорт ярышларында) җиңеп чыгучы; *чемпион бокса* — бокс чемпионы; *шахматный чемпион* — шахмат чемпионы; 2. *спорт.* (*о лошади*) чемпион (бәйгедә беренчелекне алган ат); *чемпион трехлетних жеребцов* — өч яшьлек айгырлар чемпионы; 3. *ритор. устар.* яклаучы, сакчы; *чемпион справедливости* — гаделлек сакчысы.

**ЧЕМПИОНА'Т** *м. спорт.* — чемпионат, көрәш, ярыш; *всесоюзный шахматный чемпионат* — бөтенсоюз шахмат чемпионаты.

**ЧЕМПИОНЕ'ССА** *ж. устар.*, **ЧЕМПИО'НКА** *ж. разг.* — к. чемпион.

**ЧЕМПИО'НСКИЙ** — чемпион ...-ы; чемпионлык ...-ы; *чемпионское звание* — чемпион исеме, чемпионлык дәрәҗәсе.

**ЧЕМПИО'НСТВО** *ср. мн.* нет — чемпионлык, чемпион исеме; *получить чемпионство* — чемпионлык яулап алу.

**ЧЕПЕ'Ц** *м.* — чепец (хатын-кызларның баш киеме); *ночной чепец* — төнлә киелә торган чепец.

**ЧЕПЕ'ЧНИК** *м. спец.* — чепец калыбы, чепец калыплый торган түмәр.

**ЧЕПЕ'ЧНИЦА** *ж. спец.* — чепец остасы, чепец тегүче, чепец бәйләүче.

**ЧЕПЕ'ЧНЫЙ** *спец.* — чепец ...-ы; *чепечная лента* — чепец тасмасы.

**ЧЕПИ'ГИ** — к. чапиги.

**ЧЕПРА'К** *м.* — 1. *спец.* чапрак (тиренең техник кирәк-яраклар өчен файдаланыла торган калын һәм тыгыз өлеше); 2. чапрак, ияр киезе, ияр паласы, ияр асты.

**ЧЕПРА'ЧНИК** *м. спец.* — чапракчы, ияр киезе эшләүче, ияр паласы эшләүче.

**ЧЕПУХА'** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. юк нәрсә, сафсата, буш сүз, юк-бар, мәгънәсез, ләчтит; *молоть чепуху* — сафсата сату; 2. бик вак нәрсә, берни дә тормый торган нәрсә, игътибарга лаек булмаган нәрсә, дикъкатькә лаек булмаган нәрсә, вак-төяк, чүп.

**ЧЕПУХО'ВИНА** *ж. мн.* нет, *простореч. фам.* — к. чепуха.

**ЧЕПУХО'ВЫЙ** *простореч. фам.* —1. буш, юк-бар, мәгънәсез, сай эчтәлекле; *чепуховый роман* — буш роман, мәгънәсез роман; 2. бик вак, бик кечкенә, бернигә тормаслык, игътибарга лаек булмаган, вак-төяк, юк кына; *чепуховая царапина* — вак-төяк тырналу.

**ЧЕПУШИ'СТЫЙ** *простореч. фам.* — к. чепуховый 1.

**ЧЕ'ПЧИК** *м.* — к. чепец.

**ЧЕПЫ'ГИ** — к. чапыги.

**ЧЕПЫ'ЖНИК** — к. чапыжник.

**ЧЕ'РВА** I *ж. мн.* нет, *собир.* — чага, ак корт, кәрәз күзәнәкләреннән чыкмаган бала корт (кәрәз күзәнәкләрендәге личинкалар).

**ЧЕ'РВА** II *ж. простореч.* — черви (уен картасының йөрәк сурәте төшерелгән масте).

**ЧЕРВЕОБРА'ЗНЫЙ** — суалчанга охшаган, суалчансыман; *червеобразный отросток* — суалчансыман үсенте (сукыр эчәктә).

**ЧЕРВЕ'Ц** *м. зоол.* — кортча (корткыч бөҗәк).

**ЧЕ'РВИ** — к. черва II.

**ЧЕРВИ'ВЕТЬ** *несов.* — кортлау; *яблоки, грибы червивеют* — алмалар, гөмбәләр кортлыйлар.

**ЧЕРВИ'ВИТЬ** *несов.* — кортлату; *гноить и червивить фрукты в сырых подвалах* — юеш подвалларда җиләк-җимешне черетү һәм кортлату.

**ЧЕРВИ'ВИТЬСЯ** *несов. страд.* — кортлатылу.

**ЧЕРВИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — кортлылык, кортлаганлык; *червивость груши* — грушаның кортлылыгы.

**ЧЕРВИ'ВЫЙ** — кортлы, кортлаган; *червивое яблоко* — кортлы алма, кортлаган алма.

**ЧЕРВЛЁНЫЙ** *книж. устар.* — куе кызыл, көрән кызыл, карасу кызыл.

**ЧЕРВОБИ'ТНЫЙ** *обл. спец.* — к. червобойный.

**ЧЕРВОБО'ИНА** *ж. мн.* нет, *собир. спец.* — корт тишкән алма, корт төшкән алма.

**ЧЕРВОБО'Й** *м. мн.* нет — корт төшү; *от червобоя погибло много плодов* — корт төшүдән бик күп җиләк-җимеш харап булды.

**ЧЕРВОБО'ЙНЫЙ** — корт төшкән, кортлаган; *червобойные яблоки* — корт төшкән алмалар, кортлаган алмалар; *червобойный лес* — корт төшкән урман.

**ЧЕРВО'НЕЦ** *м.* — червонец (1. *устар.* 5 яки 10 сумлык алтын акча; 2. *устар.* акча, тәңкә; 3. унлык, ун сумлык акча).

**ЧЕРВО'НКА** *ж. простореч.* — к. черва II.

**ЧЕРВО'ННЫЙ** I *устар. обл.* — кызыл, ал; *червонное золото* — кызыл алтын.

**ЧЕРВО'ННЫЙ** II — черви ...-ы; *червонный туз* — черви тузы. ◇ **Червонный валет** *разг. устар. перен.* — мут егет, җилкуар егет (буржуа-дворян семьясыннан).

**ЧЕРВОТО'ЧИНА** *ж.* — 1. корт ашаган урын, корт ашаган эзләр; *червоточина в дереве* — агачта корт юлы, корт ярыгы, агач эчендә корт ашаган урын, агач эчендәге корт эзләре; 2. корт төшү; 3. *перен. только ед.* җан газабы; *в его душе завелась какая-то червоточина* — аның җанын нәрсәдер газаплап тора.

**ЧЕРВОТО'ЧНЫЙ** — корт ашаган, корт кискән; *червоточное дерево* — корт ашаган агач, корт кискән агач.

**ЧЕ'РВЫ** *простореч.* — к. черва II.

**ЧЕРВЬ** *м.* — 1. суалчан; *дождевой червь* — яңгыр суалчаны; 2. *разг.* корт; *шелковичные черви* — ефәк кортлары; 3. *перен. ритор.* (*о человеке*) корт, бөҗәк, түбән кеше; 4. *перен. книж.* төен, корт; *червь сомнения* — шикләнү төене, шикләнү корты.

**ЧЕРВЯ'К** *м.* — 1. к. червь 1, 2, 3; 2. *тех.* винтлы тапшыргыч (тешле тәгәрмәчне әйләндерә торган винтлы вал). ◇ **Ивановский червяк** — к. ивановский. **Червяка заморить** — к. заморить.

**ЧЕРВЯКО'ВЫЙ** — суалчан ...-ы; корт ...-ы; *червяковые яички* — суалчан күкәйләре, корт күкәйләре.

**ЧЕРВЯНО'Й** — 1. к. червяковый; 2. суалчаннар өчен, кортлар өчен (булган).

**ЧЕРВЯ'ЧНЫЙ** *тех.* — винтлы; *червячная передача* — винтлы тапшыргыч.

**ЧЕРДА'К** *м.* — 1. чарлак, чардак (а. өй түбәсе белән түшәм арасындагы куышлык; *бельё развешано на чердаке* — керләр чардакта эленгән; б. шунда ясалган торак урын; *жить на чердаке* — чарлакта яшәү; в. *мор.* пароход палубасы астындагы каюта); 2. *перен. простореч. вульг. шутл.* баш, акыл; *у него чердак не в порядке* — аның башы эшләми.

**ЧЕРДА'ЧНИК** *м. простореч.* — чарлакта торучы (яшәүче), чардакта торучы (яшәүче).

**ЧЕРДА'ЧНЫЙ** — чарлак ...-ы, чардак ...-ы, чарлактагы, чардактагы; чарлакта (чардакта) урнашкан; *чердачное пространство* — чарлак (чардак) куышлыгы; *чердачное помещение* — чарлактагы (чардактагы) бүлмә.

**ЧЕРЕВИ'КИ** *м. обл.* — черевик, биек үкчәле читек (Украинада хатын-кыз аяк киеме).

**ЧЕРЁВО** *ср. обл.* — к. чрево.

**ЧЕРЁД** *м. простореч.* — чират, тәртип, нәүбәт; *стоять в череду* — чиратта тору. ◇ **Идти своим чередом** — үз нәүбәтендә бару, үз тәртибендә бару, үз уңаенда бару, үз чиратында бару, гадәттәгечә бару.

**ЧЕРЕДА'** I *ж. мн.* нет — 1. *устар.* чират, тәртип, нәүбәт, көн; *всё идёт своей чередой* — барысы да үз тәртибендә бара; *придёт и моя череда* (Даль) — минем көнем дә бер килеп җитәр; 2. *устар. обл.* вакыт, заман; 3. төркем.

**ЧЕРЕДА'** II *ж. мн.* нет, *бот.* — эт тигәнәге.

**ЧЕРЕДОВА'НИЕ** *ср.* — 1. *только ед.* (*действие*) к. чередовать; 2. (*состояние*) к. чередоваться.

**ЧЕРЕДОВА'ТЬ** *несов.* — аралаштыру, аралаштырып тору, чиратлаштыру, чиратлаштырып тору, алмаштырып тору; *чередовать труд с отдыхом* — хезмәтне ял белән аралаштырып тору.

**ЧЕРЕДОВА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. аралашу, аралашып тору, чиратлашу, чиратлашып тору, алмашып тору; *в русском языке гласный „е" нередко чередуется с „о"* — рус телендә күп кенә очракларда „е" сузыгы „о" белән чиратлаша; 2. *страд.* аралаштырылу, чиратлаштырылу.

**ЧЕ'РЕЗ** *предлог* — 1. аша, аркылы; *перейти через улицу* — урам аша чыгу, урам аркылы чыгу; *пройти через лес* — урман аша узу; *прыгнуть через забор* — койма аркылы сикерү; *оповестить через газету* — газета аша хәбәр итү; 2. *устар. простореч.* аркасында, сәбәпле; *через болезнь петь не могу* (Чехов) — авыру сәбәпле җырлый алмыйм; 3. ...-дан, ...-дән соң; *приду через час* — бер сәгатьтән килермен, бер сәгатьтән соң килермен; 4. аралаш, саен; *через каждые два дня* — һәр ике көн саен; *принимать лечебные ванны через день* — дәвалау ванналарын көн аралаш кабул итеп тору; 5. ярдәмендә; *беседа шла через переводчика* — сөйләшү тәрҗемәче ярдәмендә барды.

**ЧЕРЕЗЗЕ'РНИЦА** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — буш башаклылык, ким бөртеклелек, кысыр башак.

**ЧЕРЁМУХА** *ж.* — шомырт, муел.

**ЧЕРЁМУХОВЫЙ** — 1. шомырт ...-ы; *черёмуховое мыло* — шомырт сабыны; 2. шомырт ..., муел ..., шомырт агачыннан ясал-

ган; *черёмуховая палка* — шомырт таяк, муел таяк.

**ЧЕРЕМША'** *ж. мн.* нет, *бот.* — кыр сарымсагы.

**ЧЕРЕНКО'ВЫЙ** — чыбыкчалык...; *черенковый материал* — чыбыкчалык материал.

**ЧЕРЕНО'К** I *м.* — сап; *черенок ножа* — пычак сабы.

**ЧЕРЕНО'К** II *м.* — 1. *бот.* сабак; *черенок листа* — яфрак сабагы; 2. *с.-х.* чыбыкча, үсенте, ботак.

**ЧЕ'РЕП** *м.* — баш сөяге. ◇ **По черепу** (ударить, хватить) *вульг.* — башка кундыру, түбәгә кундыру, муен тамырына кундыру; *хвать его по черепу* — түбәсенә берне кундырды, башына берне төшерде.

**ЧЕРЕПА'ХА** *ж.* — 1. ташбака; *поезд ползет, как черепаха* — поезд ташбака кебек өстерәлеп бара; 2. *только ед.* ташбака кабыгы; *изделия из черепахи* — ташбака кабыгыннан эшләнгән әйберләр.

**ЧЕРЕПА'ХОВЫЙ** — 1. ташбака...-ы; *черепаховый суп* — ташбака шулпасы; 2. ташбака кабыгыннан эшләнгән; *черепаховый портсигар* — ташбака кабыгыннан эшләнгән портсигар.

**ЧЕРЕПА'ШИЙ** — ташбака ...-ы; *идти черепашьим шагом* — ташбака адымы белән бару.

**ЧЕРЕПА'ШИНА** *ж. мн.* нет — ташбака ите.

**ЧЕРЕПА'ШКА** *ж. зоол.* — кыр кандаласы.

**ЧЕРЕПИ'ТЧАТЫЙ** — к. черепичный 2.

**ЧЕРЕПИ'ЦА** *ж.* — черепица, чирәп (түбә ябу өчен); *крыши домов покрыты черепицей* — өй түбәләре чирәп белән ябылган.

**ЧЕРЕПИ'ЧНЫЙ** — 1. черепица ..., чирәп ..., черепицадан (чирәптән) ясалган, черепица (чирәп) белән ябылган; *черепичная крыша* — чирәп түбә, чирәп белән ябылган түбә; 2. черепица ...-ы, чирәп ...-ы; *черепичный завод* — черепица (чирәп) заводы.

**ЧЕРЕПО'К** *м.* — 1. чүлмәк ватыгы, савыт-саба ватыгы, ватык; 2. яндырылган балчык, чыныктырылган балчык (чүлмәк, савыт-саба, төрле әйберләр ясау өчен).

**ЧЕРЕПЯНО'Й, ЧЕРЕПЯ'НЫЙ** *спец.* — балчыктан эшләнгән; *черепяная посуда* — балчыктан эшләнгән савыт-саба.

**ЧЕРЕСПОЛО'СИЦА** *ж. мн.* нет — басу ашалык, җир ашалык, аралашкан басу, аралашкан җир; *система колхозного хозяйства уничтожила чересполосицу* — колхоз хуҗалыгы системасы басу ашалыкны бетерде.

**ЧЕРЕССЕДЕ'ЛЬНИК** *м.* — аркалык; *подтянуть чересседельник* — аркалыкны күтәреп бәйләү.

**ЧЕРЕСЧУ'Р** *нареч.* — артык, кирәгеннән артык, чамадан тыш, чамасыз, чиктән тыш; *вода чересчур горяча* — су чамадан тыш кайнар.

**ЧЕРЕ'ШНЕВЫЙ** — төче чия ...-ы, черешня ...-ы; *черешневое варенье* — черешня вареньесы, төче чия вареньесы.

**ЧЕРЕ'ШНЯ** *ж.* — төче чия, черешня (агачы һәм җимеше).

**ЧЕРЕШО'К** *м. разг.* — к. черенок I, II.

**ЧЕРКА'ТЬ** и **ЧЁРКАТЬ** *несов. разг.* — 1. язу, язып кына тору; *черкает письмо за письмом* — хат артыннан хат язып кына тора; 2. бозу, бозгалау, сызу, сызгалау; *черкать рукопись* — кулъязманы сызгалау; 3. сызыклар сызу.

**ЧЕРКЕ'СКА** *ж.* — черкеска, якасыз җилән (өс киеме).

**ЧЕРКЕ'ССКИЙ** — черкас...-ы; *черкесское село* — черкас авылы.

**ЧЕРКЕ'СЫ** *м.* — черкаслар, черкас халкы.

**ЧЕРКЕ'ШЕНЬКА** *ж.* — черкас хатын-кызы.

**ЧЕРКНУ'ТЬ** *сов. разг.* — язып ташлау, язып алу, язгалап алу; *черкнуть письмо* — хат язып ташлау.

**ЧЕ'РМНЫЙ** *церк. книж. устар.* — кара кызыл, куе кызыл, кучкыл кызыл.

**ЧЕРНА'ВКА** *ж. разг. устар. нар.-поэт.* — чем-кара чәчле хатын-кыз, кара тутлы хатын-кыз, каракай.

**ЧЕ'РНЕДЬ** *ж. мн.* нет — к. чернядь.

**ЧЕРНЁНЫЙ** *спец.* — каралтылган, карага буялган, кара төскә кертелгән; *чернёная сталь* — каралтылган корыч.

**ЧЕ'РНЕТЬ** *ж. зоол.* — кара үрдәк.

**ЧЕРНЕ'ТЬ** *несов.* — 1. караю, каралу, кара төскә керү; *серебро чернеет* — көмеш карала; 2. караеп күренү, караеп тору, каралып күренү, каралып тору; *вдали чернеет лес* — еракта урман караеп күренә.

**ЧЕРНЕ'ТЬСЯ** *несов.* — к. чернеть 2.

**ЧЕРНЁХОНЬКИЙ** *разг.* — чем-кара, капкара, бик кара; *выкрасил всё чернёхонько* — бөтенесен чем-кара итеп буядым.

**ЧЕРНЕ'Ц** *м. устар.* — монах.

**ЧЕРНЁШЕНЬКИЙ** *разг.* — к. чернёхонький.

**ЧЕРНИ'КА** *ж. мн.* нет — кара җиләк (агачы һәм җимеше); *варенье из черники* — кара җиләктән кайнаткан варенье.

**ЧЕРНИ'ЛА** *ед.* нет — кара, язу карасы; *фиолетовые чернила* — шәмәхә кара.

**ЧЕРНИ'ЛЬНИЦА** *ж.* — кара савыты, карасавыт; *мраморная чернильница* — мәрмәр кара савыты, мәрмәр карасавыт.

**ЧЕРНИ'ЛЬНЫЙ** — кара ...-ы; *чернильный порошок* — кара порошогы. ◇ **Чернильная война** *ирон.* — каләм сугышы (ягъни берәр мәсьәлә турында язышып бәхәс алып бару). **Чернильная душа** *разг. устар. шутл. ирон.* — кәгазь корты, кәгазь йөрәкле кеше, хәреф колы (канцелярия чиновниклары турында әйтелә). **Чернильный орех или орешек** — 1. кара чикләвеге (кайбер агачларның кәүсәләренә салынган бөҗәк күкәйләреннән барлыкка килгән һәм элек кара ясау өчен файдаланылган чикләвексыман матдә); 2. *перен. разг. ирон. устар.* к. чернильная душа. **Чернильный мешок** *анат. зоол.* — кара сыекча эшләп чыгаручы биз (түбән төзелешле организмнарда, мәсәлән, моллюскларда).

**ЧЕРНИ'ТЬ** *несов.*— 1. каралту, карага буяу, кара төскә кертү; *чернить сталь* — корычны каралту; 2. пычрату, исемен пычрату, яла ягу; *из зависти чернить товарища* — көнчелектән иптәшенә яла ягу.

**ЧЕРНИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. каралтылу, карага буялу, кара төскә кертелү; 2. пычратылу, яла ягылу.

**ЧЕРНИ'ЦА** I *ж. устар. обл.* — монахиня, монашка.

**ЧЕРНИ'ЦА** II *ж. мн.* нет, *обл.*— к. черника.

**ЧЕРНИ'ЧИНА** *разг.*— кара җиләк бөртеге, бер данә кара җиләк.

**ЧЕРНИ'ЧНИК** *м.*— кара җиләклек, кара җиләк куагы.

**ЧЕРНИ'ЧНЫЙ** — кара җиләк...-ы; *черничный куст* — кара җиләк куагы; *черничный кисель* — кара җиләк кесәле.

**ЧЕРНОБОРО'ДЫЙ** — кара сакаллы.

**ЧЕРНОБРО'ВЫЙ** — кара кашлы, каракаш; *чернобровая красавица* — кара кашлы чибәр, каракаш матур.

**ЧЕРНОБУ'РЫЙ** — кара көрән; *чернобурая лиса* — кара көрән төлке.

**ЧЕРНОБЫ'ЛЬ** *ж. мн.* нет — кара әрем.

**ЧЕРНОВА'Я** *в знач. сущ.*— к. черновик.

**ЧЕРНОВИ'К** *м.*— каралама (төзәтеп акка күчерелмәгән кулъязма).

**ЧЕРНОВО'Й** — каралама ... ; *черновое письмо* — каралама хат.

**ЧЕРНОВОЛО'СЫЙ** — кара чәчле; *черноволосый молодой человек* — кара чәчле егет.

**ЧЕРНОГЛА'ЗЫЙ** — кара күзле, каракүз; *черноглазый мальчик* — кара күзле малай.

**ЧЕРНОГОЛО'ВКА** *ж.*— карабаш (1 *бот.* үлән; 2. *зоол.* кош; 3. кара башлы хайванның кушаматы).

**ЧЕРНОГОЛО'ВЫЙ** — кара чәчле; *черноголовый мальчуган* — кара чәчле малай.

**ЧЕРНОГО'РСКИЙ** — Черногория...-ы; *черногорский народ* — Черногория халкы.

**ЧЕРНОГО'РЦЫ** *м.*— черногорецлар, черногориялеләр, Черногориядә яшәүчеләр (Югославиянең көньяк-көнбатыш өлкәсендә — Черногориядә яшәүче сербларның исеме).

**ЧЕРНОГРИ'ВЫЙ** — кара яллы.

**ЧЕРНОГРУ'ДКА** *ж.*— 1. каратүш; 2. *обл.* шелди.

**ЧЕРНОГРУ'ДЫЙ** — кара түшле, кара күкрәкле; *черногрудая курица* — кара түшле тавык.

**ЧЕРНОЗЁМ** *м. мн.* нет — кара туфрак.

**ЧЕРНОЗЁМНЫЙ** — кара туфраклы; *черноземная область* — кара туфраклы өлкә.
◇ **Чернозёмная сила** *перен. книж. ритор.*— бетмәс-төкәнмәс көч, әлегәчә беленмәгән-күренмәгән көч.

**ЧЕРНОКЛЁН** *м.* — кыр чаганы, кара өрәнге.

**ЧЕРНОКНИ'ЖИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар.*— сихерчелек, им-томчылык, өшкерүчелек, багучылык.

**ЧЕРНОКНИ'ЖНИК** *м. книж. устар.*— сихерче, им-том итүче, өшкерүче, багучы.

**ЧЕРНОКО'ЖИЕ** *мн. в знач. сущ.*— кара тәнлеләр, кара тәнле кешеләр, негрлар.

**ЧЕРНОКО'ЖИЙ** — кара тәнле; *чернокожая раса* — кара тәнле раса.

**ЧЕРНОЛЕ'СЬЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х.*— яфраклы агачлар урманы, яфраклы урман.

**ЧЕРНОЛО'З** *м. бот.*— кара тал.

**ЧЕРНОМА'ЗЫЙ** *разг. фам. чаще неодобр.*— кара, кара тәнле, кара кучкыл, кара кучкыллы; *черномазый парень* — кара малай, кара кучкыл малай.

**ЧЕРНОМО'РДЫЙ** — кара танаулы, кара борынлы; *черномордый пёс* — кара борынлы эт.

**ЧЕРНОМО'РЕЦ** *м.*— Кара диңгез флоты диңгезчесе.

**ЧЕРНОМО'РСКИЙ** — Кара диңгез ...-ы; *черноморское побережье* — Кара диңгез буе.

**ЧЕРНОО'КИЙ** *поэт.*— кара күзле, шомырт күзле; *черноокая красавица* — кара күзле чибәр, шомырт күзле чибәр.

**ЧЕРНОРАБО'ЧИЙ** — кара эшче.

**ЧЕРНОРИ'ЗЕЦ** — *м. церк. книж. устар.*— к. чернец.

**ЧЕРНОСЛИ'В** *м. мн.* нет, *собир.*— кара җимеш; *кило чернослива* — бер кило кара җимеш.

**ЧЕРНОСЛИ'ВИНА** *ж. разг.*— кара җимеш бөртеге, кара җимешнең бер данәсе.

**ЧЕРНОСО'ТЕНЕЦ** *м.*, **ЧЕРНОСО'ТЕНКА** *ж. полит.*— карагруһ, карагруһчы (элекке Россиядә карагруһ дип аталган иң реакцион монархист-погромчы партияләр члены яки гомумән иң чик реакционер); *помещик-черносотенец* — алпавыт-карагруһчы, карагруһчы алпавыт.

**ЧЕРНОСО'ТЕННЫЙ** *полит.*— карагруһчы, карагруһ...-ы; *черносотенные организации* — карагруһчы оешмалар, карагруһ оешмалары.

**ЧЕРНОСО'ТЕНСТВО** *ср. мн.* нет, *полит.*— карагруһлык, карагруһчылык.

**ЧЕРНОСО'ШНЫЙ** *истор.*— сука башыннан салым түләүче; *черносошное крестьянство* — сука башыннан салым түләүче крестьяннар (соңыннан дәүләт крестьяннары).

**ЧЕРНОСТО'П** *м. мн.* нет, *обл.*— карсыз көзге сукмак.

**ЧЕРНОТА'** *ж. мн.* нет — каралык, кара; *чернота цвета* — төс каралыгы; *чернота волос* — чәч каралыгы, чәч карасы.

**ЧЕРНОТА'Л** *м. бот.*— кара тирәк, кара тал.

**ЧЕРНОТРО'П** *м. мн.* нет, *охот.*— карсыз сукмак, кар капламаган сукмак.

**ЧЕРНОУ'СЫЙ** — кара мыеклы; *черноусый дядя* — кара мыеклы агай.

**ЧЕРНОШЁРСТНЫЙ** — кара йонлы; *черношёрстные овцы* — кара йонлы сарыклар.

**ЧЕРНУ'ШКА** *ж.*— 1. *бот.* күк чәчәк; 2. *бот.* чернушка (гөмбә); 3. *простореч. фам.* кара кучкыл, кара чәчле хатын-кыз.

**ЧЁРНЫЙ** — 1. кара; *чёрная краска* — кара буяу; *чёрный хлеб* — кара икмәк; *чёрная баня* — кара мунча; 2. *устар. обл.* пычрак, керле; *с чёрными руками, да за*

*хлеб!* (Даль) — пычрак кулларың белән ипигә сузыласың!; 3. *перен.* авыр, кайгылы, кара, караңгы; *чёрные дни* — авыр көннәр, кара көннәр; 4. *перен.* кара, мәкерле, әшәке, усал ниятле; *чёрные силы реакции* — реакциянең кара көчләре; *чёрная измена* — мәкерле хыянәт; 5. *истор.* кара; дәүләт...-ы; *чёрные земли* — кара җирләр, дәүләт җирләре (борынгы Русьта); *чёрные крестьяне* — кара крестьяннар, дәүләт крестьяннары; 6. арт, арткы, арткы як; *чёрный ход* — арткы ишек; 7. *старин.* каралама; *чёрное письмо* — каралама хат. ◇ **Держать в чёрном теле** — к. тело. **Называть белое чёрным** — акны кара дип әйтү, акны кара дип санау (берәр нәрсәне күрәләтә киресенчә аңлату). **Чёрная биржа** — кара биржа (чит ил валютасы белән яшерен сәүдә). **Чёрная кошка пробежала** — к. кошка. **Чёрная сотня** — карагруһлар, карагруһчылар. **Чёрное духовенство** — монахлар. **Чёрные списки** *дореволю. загр.* — кара исемлекләр (капиталистлар тарафыннан үзара килешеп төзелгән, эшкә кабул ителмәскә тиеш булган революцион рухтагы эшчеләр исемлеге). **Чёрный глаз** — *перен.* — яман күз. **Чёрный лес** — яфраклы урман. **Чёрный пар** — кара пар. **Чёрный передел** *истор.* — черный передел (1. иманә җирләрен һәм салымнарны яңадан бүлгәләү; 2. народникларның „Земля и воля" исемле оешмасының икегә бүленгәннән соң бер тармагына бирелгән исем). **Чёрным по белому** — бик ачык, ачык аңлаешлы, акка кара белән язылган яки төшерелгән. **Черным-черно** *разг. нар.-поэт.* — 1. капкара, том-кара, чем-кара; кап-караңгы; дөм-караңгы; 2. *перен.* иксез-чиксез күп, бихисап күп.

**ЧЕРНЬ** *ж. мн.* нет — 1. *устар. простореч.* к. чернота; 2. каралтылган көмеш; *табакерка с чернью* — каралтылган көмеш йөгертелгән тәмәке савыты; 3. *устар.* гади халык, кара халык, түбән катлау кешеләре; 4. *перен. устар. ритор. презрит.* томана халык төркеме, аңгыра халык төркеме, надан халык төркеме, томана халык, аңгыра халык, надан халык.

**ЧЕРНЯ'ВЫЙ** *простореч.* — кара тутлы, кара чәчле.

**ЧЕ'РНЯДЬ** *ж. мн.* нет, *спец.* — карасу кызыл буяу, карасу кызыл охра.

**ЧЕРНЯ'К** *м* — 1. *разг.* кара әйбер; 2. *разг.* кара шар (сайлауларда берәр кандидатурага каршы тавыш биргәндә кулланыла торган шар); *наложить черняков кому-н.* — берәр кешегә кара шар (салып) тутыру (кемнең дә булса кандидатурасына каршы тавыш бирү); 3. *простореч.* каралама; *сильно исчерканный черняк* — сызгаланып беткән каралама.

**ЧЕРПА'К** *м. обл. спец.* — черпак, соскыч, озын саплы чүмеч; *черпак экскаватора* — экскаватор черпагы, экскаватор соскычы, экскаватор чүмече.

**ЧЕРПА'ЛКА** *ж. разг.* — чүмеч, савыт (нәрсәне дә булса сосып, чумырып алу өчен).

**ЧЕРПА'ЛЬНЫЙ** — соскыч..., сосып алучы, сосып ала торган, чумыргыч, чумырып алучы, чумырып ала торган; *черпальная машина* — соскыч машина.

**ЧЕРПА'ЛЬЩИК** *м. спец.* — черпальщик, сосып алучы, сосып алып торучы (берәр производствода).

**ЧЕ'РПАТЬ** *несов.* — 1. сосу, алу, сосып алу, чумыру, чумырып алу, батырып алу; *черпать воду из кадки* — кисмәктән су чумырып алу, кисмәктән су алу; *черпать песок* — ком сосып алу; 2. *перен.* алу, табу, табып алу, җыю, җыеп алу; *черпать силы* — көч алу; *черпать знания* — белем алу.

**ЧЕ'РПАТЬСЯ** *несов. страд.* — 1. сосылу, сосып алыну, чумырылу, чумырып алыну, батырып алыну; 2. алыну; *все эти сведения черпаются из первоисточников* — бу мәгълүматлар барысы да беренчел чыганаклардан алыналар.

**ЧЕРПНУ'ТЬ** *однокр.* — сосып алу, чумырып алу, алу, батырып алу; *черпнуть воды* — су чумырып алу, су алу.

**ЧЕРСТВЕ'ТЬ** *несов.* — 1. кату, ката бару, искерү, искерә бару, кибү, кибә бару; *хлеб быстро черствеет* — ипи тиз искерә; 2. *перен.* каты күңелләнү, каты күңелләнә бару, рәхимсезләнү, рәхимсезләнә бару, кансызлану, кансызлана бару.

**ЧЁРСТВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. катылык, искергәнлек, кипкәнлек; *чёрствость корки* — ипи катысының кипкәнлеге; 2. *перен.* катылык, каты күңеллелек, рәхимсезлек, кансызлык, корылык; *чёрствость души* — күңел катылыгы.

**ЧЁРСТВЫЙ** — 1. каткан, катып беткән, искергән, искереп беткән, кипкән, кибеп беткән; *чёрствый хлеб* — искергән ипи; 2. *перен.* туң, туң йөрәкле, каты күңелле, рәхимсез, җансыз, салкын; *чёрствый человек* — каты күңелле кеше, җансыз кеше, рәхимсез кеше.

**ЧЁРТ** *м.* — 1. шайтан, җен; 2. *разг. фам. вульг.* шайтан, шайтан алгыры, җен, ләгънәт, ләгънәт төшкере, пычак кергере, чәнчелгере; *чего вы, черти, здесь расходились?* (Чехов) — нәрсә сез, шайтан алгырлары, биредә тузынасыз?; 3. *разг. фам.* ләгънәт кенә төшсен, җен алгыры, ләгыйнь; *чёрт! опять опоздал на поезд!* — ләгънәт кенә төшсен, тагын поездга соңга калдым! ◇ **До чёрта** *разг. фам.* — чиксез, иксез-чиксез, ифрат, гаять дәрәҗәдә, эт булып, эт кебек; *устал до чёрта* — эт булып арыдым. **Всё к чёрту пошло** *разг.* — бернәрсә дә чыкмады, бернәрсә дә барып чыкмады, бөтен эш юкка чыкты. **Иди к чёрту** или **ко всем чертям** — чәнчелеп кит. **Брось ты к чертям эту привычку** — ташла син шул гадәтеңне. **Какой к чёрту он инженер** — каян килеп ул инженер булсын ди. **К чёрту на рога** или **на кулички** — җәһәннәмгә, җәһәннәм тишегенә, бик еракка. **На кой чёрт** *разг. фам. вульг.* — нәрсәгә, нәрсәгә калган, нигә, нигә калган, нигә кирәк, ни пычагыма, ни шайтаныма; *на кой чёрт мне туда ходить* — ни пычагыма миңа анда ба-

рып йөрергә. **Ни к чёрту не годится** *разг. фам. вульг.*—бернәрсәгә ярамый, сукыр бер тиенгә тормый, пычагыма да ярамый, шайтаныма да ярамый. **Ни черта** *разг. фам. вульг.*—1. бернәрсә дә, пычагым да, шайтаным да; *ни черта не понимаю* — бернәрсә да аңламыйм; 2. берни дә түгел, берни түгел, бернәрсә түгел; *ни черта, сделаем* — берни түгел, эшләрбез. **У чёрта на рогах** или **на куличках** *разг. фам. вульг.* — бик еракта, җәһәннәм артында. **Чем чёрт не шутит** *разг. фам.*— белмәссең, белеп булмый; *он ещё, чем чёрт не шутит, и первым прибежит*—ул әле, белмәссең, беренче булып килеп җитәр. **Чертям тошно** *разг. фам.*— шайтаның да тончыгыр; *накурили так, что чертям тошно*—шулкадәр тарткансыз, шайтаның да тончыгыр (тын да алыр хәл юк). **Чёрт возьми** *разг. фам.* — шайтан алгыры; *чёрт возьми, опять позабыл* — шайтан алгыры, тагын онытканмын. **Чёрт дёргает** (дёрнул) или **несёт** (понёс) *разг. фам. вульг.*—шайтан кушканмы, шайтан котыртканмы, шайтаныма кирәк булганмы, нәрсәгә кирәк булган, нигә кирәк булган; *чёрт меня дёрнул так сделать* — миңа болай эшләргә шайтаныма кирәк булганмы. **Чёрт догадал** *разг.*— шайтан кушканмы, нигә кирәге бар иде. **Чёрт занёс** (**принёс**)—ни шайтаныма килгән, ни пычагыма килгән; *чёрт занёс тебя сюда* — ни шайтаныма монда килдең. **Чёрт знает** или **чёрт его знает** или **чёрт те** *разг. фам. вульг.*— шайтан белсен; *а чёрт его знает, где твоя книга*—шайтан белсен, кайдадыр синең китабың; *вышло чёрт те что* — шайтан белсен, нәрсә килеп чыкты. **Чёрт ли** *разг. фам.* - нәрсә соң, шайтанымамыни, пычагымамыни, кирәкмени соң, нигә кирәге бар; *он богат, чёрт ли ему в деньгах* (Пушкин)—ул бай, шайтанымамыни аңа акча. **(Сам) чёрт ногу сломит** — башың белән чумарсың, башың белән кереп батарсың, муеннан кереп батарсың, башыңны да алып чыга алмассың, бик буталчык; *тут чёрт ногу сломит*—моннан башыңны да алып чыга алмассың. **Чёрта с два или чёрта в стуле** *разг. вульг.*—... гына тор әле; *да чёрта с два сдвинешь этот камень* — бик кузгатмый гына тор әле син бу ташны. **Чёрт с тобой** (с вами и т. п.) *разг. фам. вульг.*— ярый, синеңчә булсын (сезнеңчә булсын, аныңча булсын, аларча булсын); *чёрт с тобой, пошли* - ярый, синеңчә булсын, әйдә киттек. **Чёрт с кем-чем** *разг. фам. вульг.*—шайтан алсын, ләгънәт төшсен, чәнчелеп китсен, кадалып китсен; *чёрт с ними, с деньгами*—чәнчелеп китсен акчасы. **Чёртом** *разг. фам.*—бик җилле, бик җилле итеп, егетләрчә; *заломил чёртом свою шапку* — бүреген бик җилле итеп кыңгыр салып куйды. **Что за чёрт** *разг. фам.*—бу ни бу, бу нәрсә тагы, бу нинди әкәмәт. **До чёртиков** *просторен.* — ләх булганчы, аяктан егылганчы, эт булганчы (эчү).

**ЧЁРТОВ** *просторен. фам.*: **обули Филю в чёртовы лапти** (поговорка) — Филяне кәкре каенга сөягәннәр, Филяне агач атка атландырганнар, алдаганнар; **чёртов палец** *мин.*— шүрәле бармагы.

**ЧЕРТА'** *ж.*—1. сызык, эз; *провести черту*—сызык сызу, сызык үткәрү; 2. *только ед.* чик, эч, арт, чит, як, тыш; *зайти за черту*—чиктән үтү, чиктән узу; *в черте города*— шәһәр эчендә; *за чертой города*— шәһәрдән читтә, шәһәр тышында; 3. *перен.* сыйфат, үзенчәлек, хасият, хосусыят, холык; *черты характера*—характер үзенчәлекләре; 4. *перен.* кыяфәт; *красивые черты лица* — матур кыяфәтле йөз. ◇ **В общих чертах** *книж.*—гомумән, вак-төягенә (детальләргә) игътибар итмичә (тукталмыйча, кагылмыйча); *рассказывать о чём-нибудь в общих чертах*—берәр нәрсә турында гомумән сөйләү, кыскача гына сөйләп бирү. **Последняя черта**—соңгы чик, ахыр чик. **Черта оседлости** *офиц. дореввол.*— утрак хәлдә яшәү мәйданының чиге (патша Россиясендә еврейләргә тору өчен билгеләнгән һәм шуннан читкә чыгып утрак тормыш алып барырга мөмкин булмаган территория).

**ЧЕРТЁЖ** *м.*—чертёж, сызым; *чертёж машины*—машина чертёжы, машина сызымы.

**ЧЕРТЁЖНАЯ** *ж. в знач. сущ.*— чертёж бүлмәсе, сызым бүлмәсе.

**ЧЕРТЁЖНИК** *м.*, **ЧЕРТЁЖНИЦА** *ж.*— чертёжник, чертёжница (чертёж сызучы, сызым сызучы).

**ЧЕРТЁЖНЫЙ**—чертёж ...-ы, сызым ...-ы; *чертёжная доска*—чертёж тактасы, сызым тактасы.

**ЧЕРТЁНОК** *м.* (*мн.* чертенята) *разг. фам.*— шайтан баласы, җен баласы, пәри баласы.

**ЧЕРТИ'ТЬ** I *несов.*—1. сызу, сызгалау; *чертить линию*—сызык сызу; *чертить на песке буквы* — комга хәрефләр сызгалау; 2. чертёж сызу, чертёж ясау, сызым сызу, сызым ясау, (планын) төшерү, сызу; *чертить план здания*—бинаның планын төшерү, сызу (чертёжын ясау).

**ЧЕРТИ'ТЬ** II *несов. просторен.*— башбаштаклык итү, дөнья җимерү, дуамаллану.

**ЧЕРТИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*—1. сызылу; 2. чертёжы (сызымы) ясалу (сызылу, төшерелү).

**ЧЕРТИ'ХА** *ж. обл.*—җен карчыгы, убырлы карчык, сихерче карчык, пәри карчыгы.

**ЧЕРТО'ВКА** *ж. разг. бран.*—җен суккан хатын, ләгънәт төшкән хатын, каһәр төшкән хатын.

**ЧЕРТО'ВСКИ** *нареч. разг. фам.*— гаять, гаять дәрәҗәдә, соң дәрәҗәдә; *чертовски устал*—гаять арыдым.

**ЧЕРТО'ВСКИЙ**—1. иблис...-ы; шайтан...-ы; җен...-ы; *чертовское наваждение* — иблис вәсвәсәсе; 2. *разг. фам.* бик күңелсез, бик әшәке, бик авыр, ләгънәт төшкән; *чертовская погода*—бик әшәке һава; *чертовская работа, никак не окончишь* — ләгънәт төшкән эш, һич кенә дә бетереп булмый.

**ЧЕРТОВЩИ'НА** *ж. мн.* нет, *разг.* — к. дьявольщина.

**ЧЕРТО'Г** *м. книж. поэт. ритор.*— гүрнәчә, пулат, сарай; *чертог сиял*—пулат ямь чәчеп тора иде.

**ЧЕРТОПОЛО'Х** *м. мн.* нет, *бот.*— шайтан таягы (чәнечкеле үсемлек).

**ЧЁРТОЧКА** *ж. разг.*— сызыкча, дефис.

**ЧЕРТЫХА'ТЬСЯ** *несов. просторечь. фам*— ләгънәтләп сүгенү, каһәрләп сүгенү, шайтанны телгә алып сүгенү, җенне телгә алып сүгенү.

**ЧЕРЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет—**1.** к. чертить 1; **2.** сызым; *уроки черчения* — сызым дәресләре.

**ЧЁС** *м.*: **задать чёсу**—1. яру, тукмау, арт сабагын укыту; **2.** *(убежать поспешно)* сызу, таю, шылу, качу.

**ЧЕСА'ЛКА** *ж. спец.* - тарак, тарагыч, тарау машинасы; *чесалка для расчёски льна*—житен тарау өчен эшләнгән тарак.

**ЧЕСА'ЛЬНЫЙ** *спец.*—тарау ...-ы, тарый торган, тарагыч; *чесальная машина*—тарау машинасы, тарый торган машина.

**ЧЕСА'ЛЬЩИК** *м.*, **ЧЕСА'ЛЬЩИЦА** *ж. спец.*— тарап торучы, тараучы; *чесальщик на отделочной фабрике* эшкәртү фабрикасында тараучы булып эшли торган эшче.

**ЧЁСАНЫЙ**— тараулы, таралган; *чёсаный лён*—тараулы җитен.

**ЧЕСА'ТЬ** *несов.*—1. кашу; *чесать руку*—кулны кашу; **2.** тарау; *чесать волосы*—чәч тарау; **3.** *перен. просторечь.* сызу, сыздыру, сибү, сиптерү (бик тиз эшләү, сөйләү, йөгерү һ. б. турында); *так и чешет* — сиптерә дә сон. ◇ **В затылке чесать или затылок чесать**—башны кашу (нинди дә булса бер авыр эш яки мәсьәлә алдында калу). **Зубы чесать**—к. зуб. **Язык чесать и языком чесать**—ләчтит сату, юк-барны сөйләү.

**ЧЕСА'ТЬСЯ** *несов.*—1. кашыну; *собака чешется*— эт кашына; 2. тарану; *он тщательно чешется* — ул бик ыктымат тарана; 3. *разг.* кычыту; *спина чешется*— арка кычыта; 4. *страд.* таралу; *лён чешется на пряжу*—җитен эрләү өчен тарала. ◇ **Чешутся руки**— к. рука **Язык чешется**—тел кычытып тора (нәрсә булса әйтү яки сөйләү өчен).

**ЧЁСКА** *ж.*—**1.** *только ед. обл.* к. чесать; **2.** *устар.* причёска (матурлап тарап куелган чәч); *модная чёска* — купшы прическа, матур итеп тарап куелган чәч; **3.** *только ед. просторечь. устар.* ләчтит сату, юк-барны сөйләү.

**ЧЕСНО'К** *м мн.* нет—сарымсак.

**ЧЕСНО'ЧИНА** *ж. обл.*— бер баш сарымсак.

**ЧЕСНО'ЧНИК** *м. бот.*—чесночник (гөмбә исеме).

**ЧЕСНО'ЧНИЦА** *ж.*—1. чесночница, сарымсак килесе; **2.** *зоол.* күрәк аяклы бака, сасы бака.

**ЧЕСНО'ЧНЫЙ**—сарымсак ...-ы; *чесночный запах*— сарымсак исе.

**ЧЕСО'ТКА** *ж. мн.* нет—**1.** *разг.* тән кычыту, тән кычу; **2.** *мед.* корчаңгы.

**ЧЕСО'ТОЧНЫЙ** *мед.*—1. корчаңгы...-ы; *чесоточный клещ* — корчаңгы бете; **2.** корчаңгы авырулы кеше; **3.** корчаңгылар...-ы, корчаңгы белән авыручылар...-ы; *чесоточная палата*—корчаңгы белән авыручылар палатасы.

**ЧЕ'СТВОВАНИЕ** *ср. книж.*—1. *только ед.* к. чествовать; **2.** котлау җыелышы, котлау тантанасы, хөрмәтләү җыелышы.

**ЧЕ'СТВОВАТЬ** *несов. книж.*— олылау; хөрмәтләү, котлау, тантаналы хөрмәт күрсәтү, тантаналы рәвештә котлау, тәбрикләү; *чествовать юбиляра*—юбилярны тантаналы рәвештә котлау.

**ЧЕ'СТВОВАТЬСЯ** *несов. страд.*—хөрмәтләнү, тантаналы хөрмәт күрсәтелү, тантаналы рәвештә тәбрикләнү.

**ЧЕСТИ'ТЬ** *несов. разг. фам.*— ... дип сүгү, ... дип тиргәү, ... дип атап сүгү; *честить негодяем*—кабахәт син дип сүгү.

**ЧЕСТНО'Й** *старин. церк.*— гыйззәтле, хөрмәтле, кадерле; *честные гости*—хөрмәтле кунаклар; *честной народ*— хөрмәтле халык. ◇ **Мать честная** *просторечь. фам.*— эхма, анакаем, анакайгынам, әнекәем, әнекәйгенәм; *мать честная! и здорово же он играет!* — анакаем! шәп уйный да соң!

**ЧЕ'СТНОСТЬ** *ж. мн.* нет—1. намуслылык, тугрылык, турылыклылык; *честность характера* — характер намуслылыгы; *в его честности н т сомнений* — аның намуслылыгында шик юк.

**ЧЕ'СТНЫЙ** — 1. намуслы, тугры, турылыклы; *честный человек*— намуслы кеше; *честный труд* — намуслы хезмәт, тугры хезмәт; **2.** намуслылык белән табылган, намуслы хезмәт белән табылган, турылык белән табылган, тугры хезмәт белән (көч түгеп) табылган; *честный заработок* — намуслы хезмәт белән табылган эш хакы; **3.** *устар.* гыйффәтле; саф; *честная девушка*—гыйффәтле кыз. ◇ **Держаться на честном слове** *разг. ирон. шутл.*—чак кына эләгеп тору, чак-чак кына эләгеп тору. **Честное слово**— билләһи (дип әйтәм), валлаһи (дип әйтәм), чынлап әйтәм, ихластыр менә; *честное слово, я не лгу* — билләһи (дип әйтәм), алдамыйм.

**ЧЕСТОЛЮ'БЕЦ** *м. книж. неодобр.*— шөһрәт яратучы кеше, хөрмәт яратучы кеше, дәрәҗә яратучы кеше, дан яратучы кеше, шөһрәт (дан, дәрәҗә) артыннан куучы кеше.

**ЧЕСТОЛЮБИ'ВЫЙ** *книж. неодобр.*— шөһрәт яратучы, хөрмәт яратучы, дәрәҗә яратучы, дан яратучы, шөһрәт (дан, дәрәҗә) артыннан куучы; *честолюбивый человек* — шөһрәт яратучы кеше.

**ЧЕСТОЛЮ'БИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. неодобр.*— шөһрәт ярату, хөрмәт ярату, дәрәҗә ярату, дан ярату, шөһрәт (дан, дәрәҗә) артыннан куу.

**ЧЕСТЬ** I *ж.*—**1.** *только ед.* намус; *долг чести* — намус кушуы; *чувство чести* — намус хисе; **2.** горурлык, мактаныч; *этот студент — честь нашего института* — бу студент — безнең институтның горурлыгы;

3. гыйффәт, гыйффәтлелек, намус, сафлык; *покуситься на честь девушки* — кызның намусына тукыну, кызның сафлыгына тап төшерергә омтылу; 4. кадер, хөрмәт, дәрәҗә, ихтирам, мәртәбә; *это большая честь для меня* — бу минем өчен зур хөрмәт (яки дәрәҗә). ◇ **В честь** (кого-чего и кому-чему) *книж.* — (кемнең яки нәрсәнең дә булса) хөрмәтенә; *в честь твоего приезда мы созвали гостей* — син килү хөрмәтенә без кунаклар чакырдык. **Выйти с честью** (из чего) — намус белән чыгу, лаеклы чыгу, абруен югалтмыйча чыгу. **Делать (сделать) честь** (кому-чему) — 1. бәясен күтәрү, шөһрәтен тагын да арттыру, дәрәҗәсен тагын да күтәрү, данын арттыру, ихтирам тудыру; *Ломоносов сделал честь своему веку* — (Даль) — Ломоносов үз гасырының дәрәҗәсен тагын да күтәрде; 2. *разг. устар.* хөрмәт күрсәтү; 3. *шутл.* к. отдавать честь 2. **Иметь честь** *офиц. разг. устар.* — бәхетенә ирешү, шәрәфенә ирешү; *имел честь сопровождать вас* (Гоголь) — сезне озатып бару бәхетенә (шәрәфенә) ирештем. **К чести** (служит) *чьей* — (аның) яхшы ягы шунда; *к чести его, он сразу исправил ошибку* — аның яхшы ягы шунда, ул (үз) ялгышын шунда ук төзәтте. **Можно чести приписать** *разг. устар.* — матурлык дип санарга мөмкин, горурлык дип санарга мөмкин. **Надо** или **пора честь знать** *разг. фам.* — житкән, чамасын белергә кирәк, әзрәк инсафлы булырга кирәк. **Отдавать честь** — 1. *воен.* честь бирү; 2. *шутл.* игътибар итү, хөрмәт күрсәтү (берәр нәрсәгә); *гости по очереди отдавали честь каждому блюду* — кунаклар үз чиратында (өстәлгә китерелгән) һәр сыйга хөрмәт күрсәтә бардылар. **Поле чести** *ритор. устар.* — сугыш кыры, сугыш хәрәкәтләре мәйданы. **Послушать** или **согласиться честью** — үз ихтыярың белән тыңлау, үз ихтыярың белән күнү. **Просить честью** — яхшылык белән сорау, яхшылык белән үтенү; *прошу честью, уходите* — яхшылык белән сорыйм, китегез. **Честь и место** — к. место.

**ЧЕСТЬ** II *ж. несов. старин.* — 1. уку; 2. ... дип уйлау,... дип санау.

**ЧЕСУНЧА', ЧЕСУНЧО'ВЫЙ** *устар.* — к. чесуча, чесучовый.

**ЧЕСУЧА'** *ж. мн.* нет — чесуча (кытай ефәге); *летний пиджак из чесучи* — чесучадан тегелгән җәйге пиджак.

**ЧЕСУЧО'ВЫЙ** — чесуча...; чесучадан тегелгән; *чесучовый пиджак* — чесуча пиджак, чесучадан тегелгән пиджак.

**ЧЁТ** *м. мн.* нет, *разг.* — җөп, җөп сан *чёт или нечёт?* — җөпме, такмы?

**ЧЕТА'** *ж. книж.* — 1. иш, тиң, пар; 2. пар, ирле-хатынлы, ир белән хатын, егет белән кәләш; *супружеская чета* — ирле-хатынлы.

**ЧЕТВЕ'РГ** *м.* — пәнҗешәмбе, кече атна көн, атна кич. ◇ **После дождика** (или **дождичка) в четверг** — кызыл кар яугач, кайчан да булса бер.

**ЧЕТВЕРЕ'НЬКИ: на четвереньки, на четвереньках** *разг. ед.* нет — дүрт аякланып; мүкәләп (йөрү), дүрт аяклану.

**ЧЕТВЕРИ'К** *м.* — 1. *спец.* четверик (дүртле үлчәүдән торган үлчәү берәмлеге, мәсәлән, дүрт пот сыйдырышлы капчык, кап һ. б.); 2. (бергә җигелгән) дүрт ат.

**ЧЕТВЕРИКО'ВЫЙ** *спец. обл.* — бер четверик, дүрт потлы; *четвериковый куль муки* — бер четверик он (дүрт пот он тутырылган капчык). ◇ **Четвериковая свеча** — дүрт данә шәм (электә 4 данә шәм махсус тартмада сатылган).

**ЧЕТВЁРКА** *ж.* — 1. *разг.* дүртле (сан, билге, уен картасы һ. б.); *четвёрка черв* — черви дүртлеге; 2. *разг.* дүртенче, дүртле (дүртле билгесе белән номерланган әйберләр, мәсәлән, трамвай, автобус, бильярд шары һ. б. турында); 3. *школьн.* дүртле билгесе, дүртле; *поставил мне четвёрку* — миңа дүртле билгесе куйды; 4. дүрт кешедән торган, дүрт; *четвёрка молодцов* — менә дигән дүрт егет; 5. *спец.* ике пар ишкәкле көймә һ. б.; 6. (бергә җигелгән) дүрт ат.

**ЧЕТВЕРНИ'** *простореч. ед.* нет — дүрт игезәк, дүрт игез(әк) бала.

**ЧЕТВЕРНО'Й** *разг.* — дүрт тапкыр артык, дүрт тапкыр арттырылган; *в четверном размере* — дүрт тапкыр артык, дүрт тапкыр артык күләмдә.

**ЧЕТВЕРНЯ'** *разг.* — к. четвёрка 6.

**ЧЕ'ТВЕРО** — дүрт, дүртәү, дүртәүләп; *четверо человек* — дүртәү, дүрт кеше.

**ЧЕТВЕРОДНЕ'ВНЫЙ** *книж.* — к. четырёхдневный.

**ЧЕТВЕРОКЛА'ССНИК** *м.*, **ЧЕТВЕРОКЛА'ССНИЦА** *ж.* — дүртенче класс укучысы.

**ЧЕТВЕРОНО'ГИЙ** — 1. дүрт аяклы; *четвероногое животное* — дүрт аяклы хайван; 2. *только мн. в знач. сущ.* дүрт аяклылар (маймыллардан башка хайваннар).

**ЧЕТВЕРОРУ'КИЙ** — 1. дүрт куллы; 2. *только мн. в знач. сущ. зоол.* дүрт куллылар (маймыллар).

**ЧЕТВЕРОСТИ'ШИЕ** *ср. лит.* — дүрт юллы шигырь, дүрт юллы шигырь строфасы.

**ЧЕТВЁРОЧНИК** *м. школьн. устар.* — дүртле билгесенә укучы, дүртлегә укучы.

**ЧЕТВЕРОЯ'КИЙ** *книж.* — дүрт төрле (юл белән мөмкинлеге булган), дүрт төрле (мөмкинлеге булган), дүрт төрле формада (мөмкинлеге булган); *четвероякий выход из положения* — (нинди дә булса) хәлдән дүрт төрле юл белән чыгу.

**ЧЕТВЕРТА'К** *м. разг.* — чирек сум, егерме биш тиен.

**ЧЕТВЕРТАКО'ВЫЙ** *разг.* — чирек сумлык..., егерме биш тиенлек...; *четвертаковая цена* — егерме биш тиенлек хак, чирек сумлык хак.

**ЧЕТВЕРТИ'НА** *ж.* — 1. *устар. обл.* к. четверть 1; 2. чирек бүрәнә (дүрткә ярылган бүрәнәнең бер кисәге).

**ЧЕТВЕРТИ'НКА** *ж.*— 1. к. четвертина 2; 2. *простореч.* четвертинка, чирушка, чирек литр (аракы яки башка эчемлек).

**ЧЕТВЕРТИТО'ННЫЙ** *муз.*— чирек тонлы (октаваны чирек тоннарга, ягъни 24 баскычка бүлүгә нигезләнгән); *четвертитонная музыка* — чирек тонлы музыка.

**ЧЕТВЕРТИ'ЧНЫЙ** *геол.*— дүртенчел; *четвертичная система* — дүртенчел система (җир төзелеше тарихында).

**ЧЕТВЁРТКА** *ж. разг.*— 1. к. четверть 1; 2. чирек бит кәгазь.

**ЧЕТВЕРТНО'Й** — 1. чирек..., чирекле, дүрттән бер..., дүрттән берле; *четвертная нота* — дүрттән берле нота; 2. *разг. устар.* 25 сумлык акча, 25 тәңкә.

**ЧЕТВЕРТОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. истор.*— ботарлап үтерү, дүрткә ботарлау (кулларын, аякларын һәм башын кисеп җәзалау).

**ЧЕТВЕРТОВА'ТЬСЯ** *несов. истор. страд.*— ботарлап үтерелү.

**ЧЕТВЕРТО'К** *м. устар.*— к. четверг.

**ЧЕТВЁРТЫЙ** — дүртенче; *четвёртый раз* — дүртенче тапкыр.

**ЧЕ'ТВЕРТЬ** *ж.*— 1. чирек, дүрттән бер, дүртенче өлеш; *на каждую четверть часа приходится 15 минут* — һәр чирек сәгатькә 15 минут туры килә; *выставить отметки за первую четверть* — беренче чирек өчен билгеләр куеп чыгу; 2. чирек, чирекле савыт, шешә (билгеле бер үлчәү күләменең дүрттән берен сыйдырышлы); *четверть вина* — бер чирек кызыл аракы (чиләкнең дүрттән бер өлеше); *четверть молока* — бер чирек сөт (өч литр); 3. *истор.* бер чирек җир (буйга 40, аркылыга 30 сажень); 4. *плотн. стол.* четверть, уем, уемты, ырмау (бер борысны икенче борыс белән ялгау өчен борыс кырына туры почмаклап киселгән уем, ырмау).

**ЧЁТКИ** *ед.* нет, *церк.*— тисбе, тәсбих.

**ЧЁТКИЙ** — 1. ачык, анык, төгәл (башкарылган һ. б.); *чёткие движения* — төгәл хәрәкәтләр; 2. ачык, ачык аңлаешлы, җиңел аңлаешлы; *чёткий шрифт* — ачык шрифт; *чёткое изложение* — ачык итеп (аңлаешлы итеп) сөйләп бирү; 3. *перен.* пөхтә эшләнгән, чиста эшләнгән, җиренә җиткереп эшләнгән; *чёткая работа* — җиренә җиткереп эшләнгән эш.

**ЧЁТКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ачыклык, аныклык, күзгә бәрелеп торганлык; 2. ачык аңлаешлылык, җиңел аңлаешлылык; 3. пөхтә эшләнгәнлек, чиста эшләнгәнлек, җиренә җиткерелеп эшләнгәнлек.

**ЧЁТНЫЙ** — җөп, парлы, икегә бүленә торган; *чётные числа* — җөп саннар.

**ЧЕТЫ'РЕ** — дүрт; *четыре делится на два* — дүрт икегә бүленә.

**ЧЕТЫ'РЕЖДЫ** *нареч.*— дүрт мәртәбә; дүрт тапкыр, дүрт җирдә; *четырежды восемь—тридцать два*—дүрт тапкыр сигез — утыз ике (дүрт сигезең — утыз ике).

**ЧЕТЫ'РЕСТА** — дүрт йөз; *четыреста студентов* — дүрт йөз студент.

**ЧЕТЫРЕУГО'ЛЬНИК** *м.*— к. четырёхугольник.

**ЧЕТЫРЕУГО'ЛЬНЫЙ** — к. четырёхугольный.

**ЧЕТЫРЁХГОДИ'ЧНЫЙ** *книж.*— дүрт еллык...; *четырёхгодичные курсы* — дүрт еллык курслар.

**ЧЕТЫРЁХГОЛО'СНЫЙ** *муз.*— дүрт тавышлы; *четырёхголосный хор* — дүрт тавышлы хор.

**ЧЕТЫРЁХГРА'ННИК** *м. мат.*— дүрткырлык.

**ЧЕТЫРЁХГРА'ННЫЙ** — дүрт кырлы; *четырёхгранный брус* — дүрт кырлы борыс.

**ЧЕТЫРЁХДНЕ'ВНЫЙ** — дүрт көнлек...; *четырёхдневный путь* — дүрт көнлек юл.

**ЧЕТЫРЁХКЛА'ССНЫЙ** — дүрт класслы.

**ЧЕТЫРЁХКОНЕ'ЧНЫЙ** — дүрт очлы.

**ЧЕТЫРЁХКРА'ТНЫЙ** — дүрт тапкыр... дүрт мәртәбә кабатланган; *четырёхкратное, обращение* — дүрт тапкыр мөрәҗәгать итү.

**ЧЕТЫРЁХЛЕ'ТИЕ** *ср. книж.*— 1. *(срок)* дүрт ел; 2. дүрт еллык; *четырёхлетие работы* — эшнең, хезмәтнең дүрт еллыгы.

**ЧЕТЫРЁХЛЕ'ТНИЙ** — 1. дүрт еллык...; *четырёхлетний срок* — дүрт еллык срок; 2. дүрт яшьлек...; *четырёхлетний ребёнок* — дүрт яшьлек бала.

**ЧЕТЫРЁХМЕ'СТНЫЙ** — дүрт урынлы, дүрт урынлык, дүрт кешелек; *четырёхместное купе* — дүрт урынлы купе.

**ЧЕТЫРЁХМЕ'СЯЧНЫЙ** — дүрт айлык; *четырёхмесячный отпуск* — дүрт айлык отпуск; *четырёхмесячный ребёнок* — дүрт айлык бала.

**ЧЕТЫРЁХПО'ЛЬЕ** *ср. мн.* нет, *с.-х.*— дүрт басулылык, дүрт кырлылык (эшкәртелә торган җирне дүрт кырга бүлеп чәчү системасы).

**ЧЕТЫРЁХПО'ЛЬНЫЙ** *с.-х.*— дүрт басулы, дүрт кырлы; *четырёхпольный севооборот* — дүрт басулы чәчү әйләнеше.

**ЧЕТЫРЁХСЛО'ЖНЫЙ** *грам.*—дүрт иҗекле; *четырёхсложное слово* — дүрт иҗекле сүз.

**ЧЕТЫРЁХСОТЛЕ'ТИЕ** *ср.*— 1. *(срок)* дүрт йөз ел; 2. дүрт йөз еллык.

**ЧЕТЫРЁХСОТЛЕ'ТНИЙ** — дүрт йөз еллык...; *четырёхсотлетний срок* — дүрт йөз еллык срок; *четырёхсотлетний юбилей* — дүрт йөз еллык юбилей.

**ЧЕТЫРЁХСО'ТЫЙ** — дүрт йөзенче; *четырёхсотый номер* — дүрт йөзенче номер.

**ЧЕТЫРЁХСТО'ПНЫЙ** — дүрт стопалы, дүрт буынлы; *четырёхстопный стих* — дүрт стопалы шигырь.

**ЧЕТЫРЁХСТОРО'ННИЙ** —дүрт яклы; *четырёхстороннее соглашение* — дүрт яклы килешү.

**ЧЕТЫРЁХСТРУ'ННЫЙ** *муз.*— дүрт кыллы; *четырёхструнный инструмент* — дүрт кыллы инструмент.

**ЧЕТЫРЁХТА'КТНЫЙ** *муз. тех.*— дүрт тактлы; *четырёхтактная пауза* — дүрт

тактлы пауза; *четырёхтактный двигатель* — дүрт тактлы двигатель.

**ЧЕТЫРЁХТА'КТОВЫЙ** *муз.*— к. четырёхтактный.

**ЧЕТЫРЁХТЫ'СЯЧНЫЙ** — 1. дүрт меңенче; 2. дүрт меңле, дүрт меңлек..., дүрт мең ...-дән торган; *четырёхтысячный отряд* — дүрт меңлек отряд.

**ЧЕТЫРЁХУГО'ЛЬНИК** *м.*— дүртпочмак.

**ЧЕТЫРЁХУГО'ЛЬНЫЙ** —дүрт почмаклы; *четырёхугольный стол* — дүрт почмаклы өстәл.

**ЧЕТЫРЁХЧАСОВО'Й** — 1. дүрт сәгатьлек..., дүрт сәгатькә сузылган; *четырёхчасовая беседа* — дүрт сәгатьлек әңгәмә; 2. *разг.* сәгать дүрттәге, сәгать дүрткә билгеләнгән; *четырёхчасовой поезд* — сәгать дүрттәге поезд.

**ЧЕТЫРЁХЧЛЕ'ННЫЙ** *книж.*— дүрт буынлы; *четырёхчленный период* — дүрт буынлы тезем.

**ЧЕТЫРЁХЭТА'ЖНЫЙ** — дүрт этажлы, дүрт катлы; *четырёхэтажный дом* — дүрт катлы йорт.

**ЧЕТЫ'РНАДЦАТЫЙ** — ундүртенче; *четырнадцатый раз* — ундүртенче тапкыр.

**ЧЕТЫ'РНАДЦАТЬ** — ундүрт; *четырнадцать человек* — ундүрт кеше.

**ЧЕТЬ** *ж.*—1. *старин. истор.* к. четверть 3; 2. *простореч. фам.* к. четверть 1, 2.

**ЧЕХАРДА'** — 1. шыгырдый, шыгырдин, сикерешле уены (бөгелгән хәлдә торучы кеше аша бер-бер артлы сикерү уены); *играть в чехарду* — шыгырдый уйнау; 2. *перен. разг. неодобр.* бик еш алмашынып тору, тәртипсезлек, буталчыклык, болгагай; *министерская чехарда*—министрларның еш алмашынып торуы, министрлык болгагае.

**ЧЕХВА'Л** *м. простореч. обл.* — мактанчык, коры куык, бушбугаз.

**ЧЕХВА'ЛИТЬСЯ** *простореч. обл. несов.*— мактану, мактанчыклану, корыкуыклану, бушбугазлану.

**ЧЕХВА'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *простореч. обл.*— мактанчыклык, корыкуыклык, бушбугазлык.

**ЧЕХВО'СТИТЬ**— к. чихвостить.

**ЧЕ'ХИ** *м.*— чехлар, чех халкы (Чехословакия республикасында яшәүче ике төп халыкның берсе).

**ЧЕХО'Л** *м.*—чехол, тышлык, япкыч, кап; *мягкая мебель в чехлах* — чехол кидерелгән йомшак мебель, тышлык кидерелгән йомшак мебель.

**ЧЕЧЕВИ'ЦА** *ж.*— 1. *только ед.* ясмык; *каша из чечевицы* — ясмык боткасы; 2. *физ.* (ясмык формасындагы) оптик пыяла, линза (бинокльләрдә, микроскопларда һ. б.).◇ **За чечевицу** или **за горшок чечевицы** —к. чечевичный.

**ЧЕЧЕВИ'ЧНЫЙ** — ясмык...-ы; *чечевичный суп* — ясмык ашы.◇ **За чечевичную похлёбку** или **за чечевичное варево** (продать, уступить что-н.) — сукыр бер тиенгә (сатып җибәрү, алмаштыру).

**ЧЕЧЕ'НКА** *ж.*— чечен хатын-кызы.

**ЧЕЧЕ'НСКИЙ** — чечен...-ы, чеченнәр...-ы; *чеченский язык* — чечен теле.

**ЧЕЧЕ'НЦЫ** *мн.*— чеченнәр, чечен халкы (Чечен-Ингуш автономияле совет социалистик республикасында яшәүче халык).

**ЧЕ'ЧЕТ** *м. зоол.*— чечет (кош).

**ЧЕЧЁТКА** *ж.*— 1. *зоол.* к. чечет; 2. *перен. разг.* тел бистәсе (хатын-кыз турында); 3. чечётка (тыпырдап бию, тыпыр-тыпыр бию).

**ЧЕЧУНЧА'. ЧЕЧУНЧО'ВЫЙ** — к. чесуча, чесучовый.

**ЧЕ'ШКА** *ж.*— чех хатын-кызы.

**ЧЕ'ШСКИЙ** — чех...-ы, чехлар...-ы; *чешская литература* — чех әдәбияты.

**ЧЕШУ'ЙКА** *ж.*—тәңкәчек, кабырчык, кабык.

**ЧЕШУ'ЙЧАТЫЙ** —1. тәңкәле, тәңкә...-лы; тәңкә кабыклы, кабырчыклы, кабырчык...-лы; *насекомые с чешуйчатыми крыльями* — тәңкә канатлы бөҗәкләр; 2. тәңкәсыман, тәңкә төсле, кабырчыксыман, кабырчык төсле.

**ЧЕШУЯ'** *ж. мн.* нет — тәңкә, кабырчык, кабык; *рыбья чешуя* — балык тәңкәсе.

**ЧИ'БИС** *м. зоол.*— бибек, тәкәрлек.

**ЧИВИ'КАТЬ** *несов.*— чутылдау, сызгыру, сызгырышу; *птички чивикают* — кошлар чутылдыйлар, кошлар сызгырышалар.

**ЧИВИ'КНУТЬ** *однокр.*— чутылдап (сызгырып) алу, чутылдап (сызгырып) кую.

**ЧИЖ** *м.*— сары чыпчык.

**ЧИ'ЖИК** *м. разг.*—1. к. чиж; 2. кыекбаш, чүрәкәй (кыекбаш уенында таяк белән сугып җибәрү өчен очлары кыеклап киселгән шакмак, чүрәкәй).

**ЧИ'ЗЕЛЬ** *м. с.-х.*— чизель (туфрак эшкәртү, йомшарту коралы); *рыхление чизелем*— (туфракны) чизель белән йомшарту.

**ЧИЙ** *м. мн.* нет. *бот.*— чий (кылган үләненең бер төре).

**ЧИК** *разг. в знач. сказ.*— чек, чек итте, чек иттерде; *ножницами чик* — кайчы белән чек иттерде.

**ЧИ'КАТЬ** *несов. разг.*— чек иттерү, чек итү, чекелдәү; *ножницы чикают* — кайчы чек итә, чекелди.

**ЧИ'КНУТЬ** *однокр. разг.*— чек итеп алу, чек иттереп алу, чекелдәп алу, чекелдәтеп алу; *ножницы чикнули* — кайчы чек иттереп алды.

**ЧИК-ЧИРИ'К** — чырылдау, чыркылдау, чер-чер итү, чыр-чыр килү (чыпчыкның, сары чыпчыкның һ. б.).

**ЧИКЧИ'РЫ** *ед.* нет, *воен. доревол.*— чикчир (тар балаклы кавалерист чалбары); *гусарские чикчиры* — гусар чикчире.

**ЧИЛИБУ'ХА** *ж. бот.*—көҗәлә (үсемлек).

**ЧИЛИ'ГА** *ж. бот.*— чилига (чәнечкеле куак, акациянең бер төре).

**ЧИЛИ'КАТЬ, ЧИЛИ'КНУТЬ**— к. чирикать, чирикнуть.

**ЧИЛЯ'ГА** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— чиләгә (Урта Азиядә үсә торган виноградның бер төре).

**ЧИН** *м.*— 1. *дореволюц.* чин, дәрәҗә; *офицерские чины* — офицерлык чиннары, дәрәҗәләре; *высокий чин* — югары чин, югары дәрәҗә; 2. *офиц. дореволюц.* хезмәткәр; *чины дипломатического корпуса* — дипломатик корпус хезмәткәрләре; 3. *только ед. стар. церк.* тәртип, йола, әдәп; *чин погребения* — күмү тәртибе, күмү йоласы. ◇ **Без чинов** *разг. шутл.*— тартынмый-нитми генә, тәкәллефсез генә.

**ЧИ'НА** *ж. бот.*— чина, кырлы борчак (үсемлек).

**ЧИНА'Р** *м.*, **ЧИНА'РА** *ж. бот.*— чинар (агач).

**ЧИНЁНЫЙ** *разг.*— ямалган; *чинёная одежда* — ямалган кием.

**ЧИНИ'ТЬ** I *несов.*— 1. төзәтү, ямау, сипләү; *чинить замки* — йозак төзәтү; *чинить платье* — күлмәк ямау; 2. очлау; *чинить карандаш* — карандаш очлау.

**ЧИНИ'ТЬ** II *несов. книж.—(устраивать, производить)* ...итү, ...эшләү, ...ясау; *чинить зло* — явызлык итү; *чинить препятствия* — киртәләр, каршылыклар ясау.

**ЧИНИ'ТЬСЯ** I *несов.* 1. *страд.* төзәтелү, ямалу, сипләнү; очлану; 2. төзәтелә алу, төзәтеп булу; *эти игрушки не чинятся* — бу уенчыкларны төзәтеп булмый.

**ЧИНИ'ТЬСЯ** II *несов. книж. страд.*— ... ителү, ... эшләнү, ... ясалу; *чинится зло* — явызлык ителә; *чинятся препятствия* — киртәләр, каршылыклар ясала.

**ЧИНИ'ТЬСЯ** III *несов. разг.*— артык кылану, артык тәкәллефләнү, чамадан тыш оялганлык күрсәтү, бөгелү-сыгылу.

**ЧИ'НКА** *ж.*— 1. *только ед. разг.* к. чинить I; 2. *простореч.* очлау машинкасы (коралы); *чинка для карандашей* — карандаш очлау коралы.

**ЧИ'ННОСТЬ** *ж. мн.* нет — әдәплелек, әдәп саклаучанлык, тәртиплелек, тәртип саклаучанлык; *чинность поведения* — үз-үзен әдәпле тоту.

**ЧИ'ННО** *нареч.*— әдәпле генә, тәртипле генә, тәртип белән; *сели чинно в ряд* — әдәпле генә тезелешеп утырдылар. ◇ **Чинно-важно** — эре генә, вәкарь белән генә, вәкарьле генә.

**ЧИ'ННЫЙ** — әдәпле, тәртипле, үз-үзен тота белүчән, йола саклаучан.

**ЧИНО'ВНИК** *м.*— чиновник, түрә (1. *дореволюц. загр.* дәүләт учреждениесе хезмәткәре; 2. *перен. неодобр.* бюрократ, формалист; *это не администратор, а чиновник* — администратор түгел, чиновник бу; 3. *церк.* архиерей укый торган догалык китабы).

**ЧИНО'ВНИЦА** *ж. дореволюц. загр.*—чиновник хатыны.

**ЧИНО'ВНИЦКИЙ** *разг. устар.*— чиновник...-ы, чиновниклык...-ы; *чиновницкое содержание* — чиновник хезмәт хакы.

**ЧИНО'ВНИЧЕСКИЙ** *книж.*— к. чиновничий.

**ЧИНО'ВНИЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *дореволюц. загр. собир.*—чиновниклар, чиновниклык итүчеләр, түрәләр, түрәлек итүчеләр; *собралось всё чиновничество* — бөтен чиновниклар җыелды.

**ЧИНО'ВНИЧИЙ** — чиновник...-ы, чиновниклык...-ы, чиновникларча..., чиновникларда була торган; *чиновничье отношение* — чиновникларча мөнәсәбәт.

**ЧИНО'ВНЫЙ** *устар* — 1. чинлы, дәрәҗәле (элек дәүләт учреждениеләрендә хезмәт итүчеләр турында); *весь чиновный народ* — барлык чинлы халык; 2. югары чинлы, югары дәрәҗәле; *чиновное лицо* — югары чинлы кеше.

**ЧИНОДРА'Л** *м. разг. презрит.*— к. чиновник 1.

**ЧИНОНАЧА'ЛИЕ** *офиц. дореволюц. теперь ирон.*— чинлылык дәрәҗәләре, чинлылык баскычлары, чиннар иерархиясе, түрәлек дәрәҗәләре, түрәлек баскычлары, түрәлек иерархиясе; *соблюдать чиноначалие* — түрәлек дәрәҗәләрен саклау.

**ЧИНОПОЧИТА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. устар. теперь ирон.*— чинга баш ию, чинны ихтирам итү, түрәлеккә баш ию, түрәлекне ихтирам итү; *правила чинопочитания* — чинга баш ию кагыйдәләре.

**ЧИНОПРОИЗВО'ДСТВО** *ср. мн.* нет, *офиц. дореволюц.*— чинга мендерү, чинга күтәрү, чин бирү, дәрәҗәгә мендерү, дәрәҗәгә күтәрү, дәрәҗә бирү.

**ЧИНУ'ША** *м. разг. презрит. пренебр.*— к. чиновник 1, 2.

**ЧИ'РЕЙ** *м.*— чуан, сызлавык.

**ЧИРЁНОК** *м.*— чүрәкәй баласы, чүрәкәй үрдәк баласы.

**ЧИРИ'КАТЬ** *несов.*— чыркылдау, чыркылдашу, чырлау, черкелдәү, черкелдәшү, черелдәү, чыелдау, чыелдашу.

**ЧИРИ'КНУТЬ** *однокр.*— чыркылдап кую, чыркылдашып кую, чырлап кую, черкелдәп кую, черкелдәшеп кую, черелдәп кую, чыелдашып кую.

**ЧИРК** *в знач. сказ. разг.*— (чырк итеп) сызды; *чирк спичками*—шырпы белән чырк итеп сызды.

**ЧИ'РКАТЬ** *несов.*— (чырк итеп) сызу; *чиркать спичками* — (чырк итеп) шырпы сызу.

**ЧИ'РКНУТЬ** *однокр.*—(чырк итеп) сызып җибәрү; *чиркнуть спичками* — (чырк итеп) шырпы сызып җибәрү.

**ЧИРО'К** *м.*, **ЧИРУ'ХА** *ж. зоол.*— чүрәкәй (үрдәкнең бер төре).

**ЧИРЯ'ТИНА** *ж. мн.* нет, *обл.*— чүрәкәй үрдәк ите.

**ЧИ'СЛЕННИК** *м. простореч.*—календарь.

**ЧИ'СЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— сан, исәп; *численность населения* — халык исәбе; *численность войска* — гаскәр саны.

**ЧИ'СЛЕННЫЙ** *книж.*— сан ягыннан, исәп ягыннан; *численное превосходство* — сан ягыннан өстенлек.

**ЧИСЛИ'ТЕЛЬ** *м. мат.*—санаучы; *в дроби 3/5 числитель 3, а знаменатель 5*—3/5 вакланмасының санаучысы 3, ә ваклаучысы 5.

**ЧИСЛИ'ТЕЛЬНЫЙ: имя числительное** — сан исеме, сан.

**ЧИ'СЛИТЬ** *несов.*— 1. *книж. устар.* исәбен санау; *числить дни* — көннәр исәбен санау; 2. *офиц.* санау, исәпләү; *числить больным* — авыру дип исәпләү.

**ЧИ'СЛИТЬСЯ** *несов. страд. офиц.*—саналу, исәпләнү; *числиться больным* — авыру дип исәпләнү; *числиться в командировке*—командировкада саналу.

**ЧИСЛО'** *ср.*— 1. сан; *целое число* — бөтен сан; *единственное число* — берлек сан; 2. *старин.* цифр; 3. көн, число; *в первых числах мая* — майның беренче көннәрендә; 4. *только ед.* исәп, сан; *число книг в библиотеке сильно возросло* — библиотекадагы китапларның саны бик нык артты; *числом поболее* — исәп ягыннан күбрәк. ◇ **В числе присутствующих** — катнашучылар арасында. **В том числе** — шул исәптән. **Без числа** — исәпсез-хисапсыз күп, бихисап күп.

**ЧИСЛОВО'Й** *книж.*— сан...-ы, сан ягыннан, санга нисбәтән; *числовая величина* — сан зурлыгы; *числовое соотношение* — сан ягыннан үзара бәйләнеш (мөнәсәбәт).

**ЧИ'СТЕНЬКИЙ** - чиста гына, бик чиста.

**ЧИ'СТИК** *м. зоол.*— чистик (акчарлакка охшашлырак төньякта яшәүче су кошы).

**ЧИСТИ'ЛИЩЕ** *ср. рел.*— тәмуг, җәһәннәм.

**ЧИСТИ'ЛЬНЫЙ** *тех.*— тазарту...-ы, чистарту...-ы, арчу...-ы, чистарткыч; *чистильная машина* — чистарту машинасы.

**ЧИ'СТИЛЬЩИК** *м.*, **ЧИ'СТИЛЬЩИЦА** *ж.*— тазартучы, чистартучы; *чистильщик сапог* — итек чистартучы.

**ЧИ'СТИТЬ** *несов.*— 1. тазарту, чистарту, арындыру; *чистить сапоги*—итек чистарту; *чистить зубы* — теш чистарту; 2. арчу; *чистить апельсин* — апельсин арчу.

**ЧИ'СТИТЬСЯ** *несов.*— 1. чистарыну, тазарыну; 2. *страд.* чистартылу, тазартылу, арындырылу; арчылу.

**ЧИ'СТО** — 1. *нареч.* чиста, чиста итеп; *чисто одеваться* — чиста киенү; 2. *союз* нәкъ, нәкъ ... шикелле, кебек, шикелле, төсле, ... диярсең; *свистит, чисто флейта*— нәкъ флейта шикелле сызгыра; 3. тулысы белән; бөтенләе белән, бары тик; *это — чисто техническая работа* — бу — тулысы белән техник эш.

**ЧИСТОВИ'К** *м. разг.*— аклама, акка күчерелгән (язылган) кульязма.

**ЧИСТОВО'Й** — 1. аклама..., аклама итеп язылган, акка күчерелгән (язылган); *чистовая рукопись* — аклама кульязма, акка күчерелгән кульязма; 2. аклама...-ы, акка күчерү (язу)...-ы; *чистовая тетрадь* —аклама дәфтәре.

**ЧИСТОГА'Н** *м. мн.* нет, *простореч.*— саф акча; *заплатить чистоганом* — саф акча белән түләү, акчалата түләү.

**ЧИСТОКРО'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет — (саф) токымлылык, (саф) нәселлелек; *чистокровность жеребца* — айгырның (саф) токымлылыгы.

**ЧИСТОКРО'ВНЫЙ**—1. *с.-х.* (саф) токымлы, (саф) нәселле; 2. *перен.* саф, чын, асыл, бөтен җире дә килгән, җиренә җиткерелгән.

**ЧИСТОПИСА'НИЕ** *ср. мн.* нет — матур язу; *урок чистописания* — матур язу дәресе.

**ЧИСТОПЛЕМЁННЫЙ** —к. чистокровный.

**ЧИСТОПЛО'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет — чисталык ярату, чисталык саклау, пакьлек ярату, пакьлек саклау, пөхтәлек ярату, пөхтәлек саклау.

**ЧИСТОПЛО'ТНЫЙ** — 1. чисталык яратучы, пакьлек яратучы, пөхтәлек яратучы, пөхтә; *чистоплотный человек* — чисталык яратучы кеше, пөхтә кеше; 2. *перен.* мораль саф, намуслы; *чистоплотная натура* — мораль саф табигатьле кеше.

**ЧИСТОПЛЮ'Й** *м. разг. пренебр.* — жирәнүчән көяз кеше, җирәнүчән купшы кеше, талымчан кеше.

**ЧИСТОПЛЮ'ЙСТВО** *ср. мн.* нет, *разг. пренебр.* — җирәнүчән көязлек, җирәнүчән купшылык, талымчанлык.

**ЧИСТОПОРО'ДНЫЙ** *с.-х.* — к. чистокровный.

**ЧИСТОПСО'ВЫЙ** *охот.*— саф токымлы, саф нәселле (эт турында).

**ЧИСТОСЕРДЕ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — саф күңеллелек, ихлас күңеллелек, саф йөрәклелек, эчкерсезлек.

**ЧИСТОСЕРДЕ'ЧНЫЙ** *книж.* — саф күңелле, ихлас күңелле, саф йөрәкле, эчкерсез; *чистосердечный человек* — саф күңелле кеше.

**ЧИСТОСО'РТНЫЙ** *спец.* — чиста сортлы; *чистосортное зерно* — чиста сортлы ашлык.

**ЧИСТОТА'** *ж. мн.* нет —1. чисталык, керсезлек, пөхтәлек, тазалык; *чистота помещения* — бинаның чисталыгы; 2. сафлык, эчкерсезлек; *чистота души* — күңел сафлыгы; *чистота намерений* — теләкләрнең эчкерсезлеге; 3. ачыклык; *чистота красок* — буяуларның ачыклыгы; 4. аңлаешлылык; *чистота слога* — стильнең аңлаешлылыгы; 5. пөхтәлек, пөхтә эшләнгәнлек; *чистота работы* — эшнең пөхтәлеге. ◇ **На чистоту** — ачыктан-ачык, бернәрсәне яшермичә.

**ЧИСТОТЕ'Л** *м. бот.* — канлы үлән.

**ЧИ'СТЫЙ** — 1. чиста, таза, ару, керсез; *надеть чистое платье* — чиста күлмәк кию; 2. саф; *чистый воздух* — саф һава; *чистое золото* — саф алтын; *чистый доход* — саф керем; 3. *перен.* саф, намуслы, керсез, эчкерсез; *чистая душа* — керсез күңел; 3. *только. ед. полн. формы* чиста, буш, ачык; *чистое поле* — ачык кыр; 4. чиста, саф, ачык, ачык аңлаешлы; *чистая интонация* — чиста интонация; *чистый звук* — ачык тавыш; 5. чиста, чиста башкарылган, пөхтә, пөхтә башкарылган, җиренә җиткерелгән; *чистая работа* — пөхтә башкарылган эш; 6. *разг.* нәкъ, нәкъ ... шикелле, әйтерсең(лә), ... диярсең; *эти стихи — чистый Пушкин* — бу шигырьләр — нәкъ Пушкин шигырьләре; 7. *разг* ...-ның нәкъ үзе, бары тик ... гына; *чистая выгода*

*взяться за это дело* — бу эшкә алыну бары тик файда гына; *чистый вздор* — сафсатаның нәкъ үзе; 8. *разг. фам. шутл.* коп-коры, буп-буш, бернәрсәсез, чеп-чиста; *сели за карты, через два часа я был чист* — карта уйнарга утырдык, ике сәгатьтән соң мин инде бернәрсәсез калдым (ягъни, оттырып бетердем). ◇ **Выйти чистым** *разг.* — судан коры чыгу (гаепләнерлек эйбердән котылу). **За чистую монету** (принимать что-н.) — к. монета. **Чистая отставка** *разг. устар.* — бөтенләйгә отставкага чыгу. **Чистой воды** — менә дигән, иң яхшы. **Чистые деньги** *разг.* — саф акча. **Чистый вес** *торг.* — (товарның) саф авырлыгы.

**ЧИСТЮ'ЛЯ** *м.* и *ж. разг. фам.* — гаять дәрәҗәдә чисталык яратучы кеше, соң дәрәҗәдә жирәнүчән кеше, гаять дәрәҗәдә талымчан кеше.

**ЧИСТЯ'К** *м.* — 1. *бот.* фикария (үсемлек); 2. *простореч.* к. чистюля.

**ЧИТА'БЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — жиңел укылучанлык, жиңел укылу, күңел биреп укылу.

**ЧИТА'БЕЛЬНЫЙ** — жиңел укылучан, жиңел укыла торган, күңел биреп укыла торган.

**ЧИТА'ЕМОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — укылучанлык, укылу.

**ЧИТА'ЕМЫЙ** *книж.* — 1. укыла торган; 2. күп укыла торган, яратып укыла торган, популяр; *читаемый роман* — күп укыла торган роман.

**ЧИТА'ЛКА** *ж.* — 1. *школьн.* к. читальня; 2. *устар.* китап аслыгы, китап терәткеч, китап сөягеч (китап уку өчен).

**ЧИТА'ЛЬНЫЙ** — уку ...-ы; *читальный зал* — уку залы.

**ЧИТА'ЛЬНЯ** *ж.* — уку бүлмәсе, уку бинасы, уку өе; *читальня в клубе* — клубта уку бүлмәсе.

**ЧИТА'ТЕЛЬ** *м.* — укучы; *литература для юных читателей* — яшь укучылар өчен әдәбият; *зал вмещает двести читателей* — зал ике йөз укучыны сыйдыра, залга ике йөз укучы сыя.

**ЧИТА'ТЕЛЬСКИЙ** — укучы ...-ы, укучылар...-ы; *внимательно относиться к читательским интересам* — укучы интересларына игътибарлы мөнәсәбәттә булу.

**ЧИТА'ТЬ** *несов.* — 1. уку; *читать по слогам* — иҗекләп уку; *читать классиков* — классикларны уку; *читать лекцию* — лекция уку; 2. *книж. перен.* күрү, тою, күреп тору, сизеп тору; *читать на лице печаль* — кайгысы барын чыраеннан тою; *читать в сердце радость* — күңелендә шатлык барлыгын сизү; 3. аңлату, аңлатып бирү, мәгънә бирү, төшендерү; *режиссёр по-новому читает пьесу* — режиссёр пьесаны яңача аңлата; 4. укыту; *он читает в университете* — ул университетта укыта. ◇ **Читать в сердцах** — (кемнең дә булса) теләкләрен, фикерләрен сизү, аңлау (тою, күреп тору). **Читать между строк** — юл арасын уку, кинаясен аңлау (автор тарафыннан турыдан-туры әйтеп бирелмәгән фикерләрне аңлау). **Читать нотации** (мораль, нравоучения) — үгет-нәсихәт бирү, мораль уку, үгетләү.

**ЧИТА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. укылу, укып булу; *эти два слова в рукописи совсем не читаются* — кулъязмада бу ике сүз бөтенләй укылмыйлар, кулъязмада бу ике сүзне бөтенләй укып булмый; 2. *книж. перен.* сизелү, сизелеп тору, тоелу, тоелып тору, бәрелеп тору; *в глазах читалась апатия* — күзләреннән күңел төшенкелеге сизелеп тора иде; 3. *страд.* укылу; *роман читается всеми* — роман барлык кеше тарафыннан укыла (ягъни, романны барлык кешеләр укый).

**ЧИ'ТКА** *ж.* — 1. *разг.* уку, кычкырып уку; *проводить коллективную читку* — күмәк уку үткәрү; 2. *театр.* уку, укып чыгу, укып танышу (пьесаны уку рәвешендә репетиция үткәрү); *читка ролей* — рольләрне уку.

**ЧИХ** *разг.* — 1. *в знач. сказ.* төчкереп җибәрде; 2. *междом.* эпчехи (төчкерү тавышы).

**ЧИХА'ТЕЛЬНЫЙ** — 1. төчкергәндә була торган; *чихательная судорога* — төчкергәндә була торган көзән җыеру; 2. төчкертә торган, төчкертүче; *чихательный газ* — төчкертә торган газ.

**ЧИХА'ТЬ** *несов.* — 1. төчкерү; *чихать при насморке* — томау төшкәндә төчкерү; 2. *простореч. вульг.* санга сукмау, санашмау, бернәрсә белән дә исәпләшмәү, төкерү; *чихать мне на него* — төкерәм мин аңа.

**ЧИХВО'СТИТЬ** или **ЧЕХВО'СТИТЬ** *несов. простореч. фам.* — 1. сугү, тетү, тетеп салу, эттән алып эткә салу; *они господ чихвостили* — алар байларны сүктеләр; 2. *перен.* тетмәсен тетү, пыран-заран китерү, кирәген бирү; *чихвостить бандитов* — бандитларны пыран-заран китерү.

**ЧИХИ'РЬ** *м. мн.* нет — чихир, чагыр (Кавказ эчемлегенең виноградтан ясалган бер төре).

**ЧИХНУ'ТЬ** *сов.* — төчкереп җибәрү.

**ЧИХЧИ'РЫ** *ед.* нет, *воен. доревол.* — к. чикчиры.

**ЧИЧЕРО'НЕ** *м. нескл.* — чичероне, күрсәтеп, аңлатып йөрүче (музейларда, берәр җирнең игътибар итәрлек, атаклы урыннарында туристларга аңлатып йөрүче).

**ЧИЧИСБЕ'Й** *м. разг. шутл.* — чичисбей, берәр хатын-кызның даими юлдашы (кавалеры, егете).

**ЧИ'ЩЕНЫЙ** — чистартылган, тазартылган, әрчелгән; *чищеный картофель* — әрчелгән бәрәңге.

**ЧКНУТЬ** *сов. обл.* — төртү, төртеп җибәрү, сугу, кундыру.

**ЧЛЕН** *м.* — 1. член, әгъза; *член общества* — җәмгыять члены; *член профсоюза* — профсоюз члены; *член клуба* — клуб әгъзасы; 2. әгъза, орган (гәүдәдә); 3. *мат.* буын; *члены математической пропорции* — математик пропорция буыннары; 4. *грам.* кисәк; *члены предложения* —

җөмлә кисәкләре; 5. *только мн. мор.* кисәкләр, өлешләр (корабль төзүдә кулланыла торган борыслар һәм агач материаллар турында); *наборные члены* — жыела торган өлешләр, кисәкләр; 6. *грам.* сүз, кисәкчә (ярдәмлек сүзләр турында); *постпозитивный член* — постпозитив кисәкчә.

**ЧЛЕ'НИК** *м. анат.* — буынтык (кыслаларда, бөҗәкләрдә).

**ЧЛЕНИСТОНО'ГИЕ** *мн. в знач. сущ. зоол.* — буынтыкаяклылар (кыслалар, үрмәкүчләр һ. б.).

**ЧЛЕНИ'ТЬ** *несов. книж.* — аерым кисәкләргә ваклау, аерым кисәкләргә аеру, аерым кисәкләргә бүлү.

**ЧЛЕНИ'ТЬСЯ** *несов. книж.* — аерым кисәкләргә ваклану, аерым кисәкләргә аерылу, аерым кисәкләргә бүленү, бүлгәләнү; *тело членистоногих членится на отдельные сегменты-членики* — буынтыкаяклыларның гәүдәсе аерым сегментларга-буынтыкларга бүленә.

**ЧЛЕНОВРЕДИ'ТЕЛЬ** *м. книж. офиц.* — берәр әгъзасын (юри) имгәтүче кеше, берәр органын (юри) имгәтүче кеше.

**ЧЛЕНОВРЕДИ'ТЕЛЬСКИЙ** *книж. — офиц.* — (юри, усал ният белән) әгъза имгәтү ...-ы, орган имгәтү ...-ы; *членовредительский акт* — (юри) әгъза имгәтү акты (эше).

**ЧЛЕНОВРЕДИ'ТЕЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. офиц.* — (юри) әгъза имгәтү, бозу (гадәттә үз-үзеңне имгәтү турында).

**ЧЛЕНОРАЗДЕ'ЛЬНО** *нареч.* — ачык итеп, аңлаешлы итеп; *говорить членораздельно* — аңлаешлы итеп сөйләү.

**ЧЛЕНОРАЗДЕ'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — ачык аңлаешлылык.

**ЧЛЕНОРАЗДЕ'ЛЬНЫЙ** *книж.* — 1. ачык аңлаешлы кисәкләрдән торган, ачык аңлаешлы авазлардан (сүзләрдән) торган; *членораздельная речь* — ачык аңлаешлы авазлардан (сүзләрдән) торган сөйләм; 2. *разг.* аңык, ачык, аңлаешлы.

**ЧЛЕ'НСКИЙ** — әгъзалык ...-ы, членлык...-ы; *членский билет* — членлык билеты.

**ЧЛЕ'НСТВО** *ср. мн.* нет — әгъзалык, әгъза булып тору, членлык, член булып тору; *профсоюзное членство* — профсоюзда член булып тору.

**ЧМОК** *в знач. сказ.* — 1. чапылдатып куйды, чупылдатып куйды; *он чмок губами* — ул иреннәрен чапылдатып куйды; 2. чуп иттерде, чупылдатып үпте; *он чмок её в губки* — ул аның иреннәреннән чупылдатып үпте.

**ЧМО'КАНИЕ** *ср.* — 1. к. чмокать; 2. чупылдау тавышы, чапылдау тавышы, лачкылдау тавышы.

**ЧМО'КАТЬ** *несов. разг.* — 1. чупылдату; *чмокать губами* — иреннәрне чупылдату; 2. чөңгерү; *чмокать, понукая коня* — чөңгереп ат куу; 3. чапылдау, лачкылдау; *грязь чмокает под ногами* — аяк астында пычрак лачкылдый; 4. *фам.* үбү, чуп итеп үбү; *чмокать девочку в щеки* — кыз баланың яңакларын чуп итеп үбү.

**ЧМО'КАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — үбешү.

**ЧМО'КНУТЬ** *сов. разг.* — 1. чупылдатып алу, чапылдатып алу; 2. чөңгереп алу; *чмокнул губами* — ирен чөңгереп алды; 3. *фам.* үбеп алу, чуп итеп үбеп алу.

**ЧМО'КНУТЬСЯ** *сов. разг. фам.* — үбешү, үбешеп алу.

**ЧО'БОТ** *м. обл.* — итек, башмак.

**ЧО'ГЛОК** *м. зоол.* — чоглок (лачыннар семьялыгына караган ерткыч кош).

**ЧО'КАНЬЕ** I *ср. разг.* — к. чокаться.

**ЧО'КАНЬЕ** II *ср. мн.* нет, *лингв.* — чылаштыру; *вятское чоканье* — вятка чылаштыруы („ц" урынына „ч" дип әйтү, мәсәлән, „целое" урынына „челое" дию).

**ЧО'КАТЬ** *несов.* — чылаштыру, чылаштырып сөйләү.

**ЧО'КАТЬСЯ** *несов. разг.* — чәкешү, чәкештерү; *чокаться рюмками с товарищами* — иптәшләр белән рюмка чәкештерү.

**ЧО'КНУТЬСЯ** *сов. разг.* — чәкешеп алу, чәкештереп алу.

**ЧО'ЛКА** *ж.* — 1. маңгай ялы (атта); 2. маңгай чәче, тигезләп киселгән маңгай чәче; *носить челку* — маңгай чәче йөртү; 3. *истор.* чолка (борынгы Русьта байрак, байрактагы билге).

**ЧО'МГА** *ж. зоол.* — агулы гөмбә.

**ЧО'ПОРНОСТЬ** *ж. мн.* нет — кыланчыклык, һавалылык, назлылык, тәкәллефлелек.

**ЧО'ПОРНЫЙ** — кыланчык, чытлык, һавалы, назлы, тәкәллефле; *чопорный человек* — кыланчык кеше; *чопорный ответ* — тәкәллефле җавап.

**ЧОХ** *устар.* — к. чих.

**ЧОХА'** *ж. обл.* — җилән, җөббә.

**ЧО'ХОМ** *нареч. разг. фам.* — тулаем, күмәртә, санап-сайлап (үлчәп-тартып) тормыйча (сату).

**ЧРЕВА'ТЫЙ** *книж.* — китереп чыгарырлык, барлыкка китерерлек, тудырырлык, сәбәп булырлык; *событие, чреватое самыми неожиданными последствиями* — бер дә көтелмәгән нәтиҗәләр тудырырлык вакыйга.

**ЧРЕ'ВО** *ср. церк. книж. поэт. устар.* — карын, корсак, эч. ◇ **(Еще) во чреве матери** *книж. ритор.* — анадан туганчы, ана карынында вакытта ук, тумас борын ук.

**ЧРЕВОВЕЩА'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — эчтән сөйләү (иреннәрне кыймылдатмыйча, гүяки эчтән чыккан тонык тавыш белән сөйли белү).

**ЧРЕВОВЕЩА'ТЕЛЬ** *м. книж.* — эчтән сөйли алучы кеше.

**ЧРЕВОУГО'ДИЕ** *ср. мн.* нет, *книж.* — ашау өчен генә яшәү, корсак файдасы өчен генә яшәү, бирәнлек.

**ЧРЕВОУГО'ДНИК** *м. книж.* — ашау өчен генә яшәүче кеше, корсак файдасы өчен генә яшәүче кеше, бирән.

**ЧРЕВОУГО'ДНИЧАТЬ** *несов. книж.* — ашау өчен генә яшәү, корсак файдасы өчен генә яшәү, бирән булу, бирәнгә сабу.

**ЧРЕДА'** *ж. церк. книж. поэт. устар.*— 1. к. черёд; 2. *ритор.* өлкә, юл (эшчәнлек турында); *счастлив, кто на чреде трудится знаменитой* (Крылов)— бөек эшчәнлек өлкәсендә хезмәт итүче кеше бәхетле.

**ЧРЕЗ** *книж. устар.*— к. через.

**ЧРЕЗВЫЧА'ЙНО** *нареч.*— бик, гаять, чиктән тыш, гадәттән тыш.

**ЧРЕЗВЫЧА'ЙНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— гадәттән тышлык, чиктән тышлык, сирәк очрый торганлык, зурлык, көчлелек, кирәгеннән артыклык.

**ЧРЕЗВЫЧА'ЙНЫЙ** *книж.*— 1. гадәттән тыш, чиктән тыш, сирәк очрый торган, көчле; *пьеса имела чрезвычайный успех*— пьеса гадәттән тыш уңыш казанды; 2. *офиц.* ашыгыч, махсус; *чрезвычайные расходы*— ашыгыч (махсус) расходлар; *чрезвычайное заседание*— махсус утырыш.

**ЧРЕЗМЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— чиктән тыш күплек, чамасызлык, чамадан тыш күплек, чамасыз күплек, чамасыз зурлык.

**ЧРЕЗМЕ'РНЫЙ** *книж.*— чиктән тыш күп, чамасыз күп, чамадан тыш зур, чамасыз зур, кирәгеннән артык, көчле; *чрезмерное внимание*— кирәгеннән артык игътибар; *чрезмерные требования*— чиктән тыш зур таләпләр, чамасыз зур таләпләр.

**ЧРЕ'СЛА** *ед.* нет, *церк. книж. устар.*— бил. ◇ **Препоясать свои чресла**— к. препоясать.

**ЧТЕ'НИЕ** *ср.*—1. *только ед.* к. читать 1, 3; 2. *только ед.* уку объекты, уку өчен билгеләнгән объект (әйбер), китап; *достал интересное чтение*— уку өчен бик кызыклы китап таптым; 3. *книж.* лекция; *чтения о русском языке*— рус теле турындагы лекцияләр.

**ЧТЕЦ** *м.*—1. укучы, кычкырып укучы (язганны); 2. тәэсирле итеп укый белүче кеше, сәнгатьчә итеп укый белүче; *конкурс чтецов*— сәнгатьчә итеп укый белүчеләр конкурсы.

**ЧТЕ'ЦКИЙ** *спец.*— тәэсирле итеп укый белүче кеше ...-ы, сәнгатьчә итеп укый белүче ...-ы; *чтецкое искусство*— тәэсирле итеп укый белүче кеше осталыгы.

**ЧТИ'МЫЙ** *книж.*— хөрмәт ителә торган, хөрмәтләнүче, хөрмәт ителүче, олылана торган, олыланучы; *всеми чтимый общественный деятель*— бөтен кеше тарафыннан хөрмәт ителә торган җәмәгать эшлеклесе.

**ЧТИТЬ** *несов. книж.*— хөрмәтләү, хөрмәт итү, олылау, искә алу.

**ЧТИ'ЦА** *ж.*— к. чтец 1.

**ЧТО** I *местоим.*—1. нәрсә, ни; *что случилось?*— нәрсә булды? *что с вами?*— сезгә ни булды? *я знаю, что это такое*— мин моның нәрсә икәнен беләм; *чего не бывает в жизни!*— тормышта ниләр генә булмый! 2. *в знач. сказ.* ни хәл, ничек, ни хәлдә; *что больной?*— авыруның хәле ничек? авыру ни хәлдә? *что ваша работа?*— эшегез ничек? 3. ник, нигә, нәрсәгә, ни өчен, нилектән, ни сәбәптән; *что ты так кричишь?*— нигә болай кычкырасың? *что ты призадумался?*— ни сәбәптән уйга калдың? 4. *разг.* күпме, ни хак; *что стоит эта книжка?*— бу китап ни хак тора? *что возьмёшь за работу?*— эшләгән өчен күпме алырсың? 5. *разг.* бөтен, кадәр; *что есть сил бросился бежать*— бөтен көченә йөгерергә тотынды; 6. *разг.* күпме, никадәр; *что сил потрачено!*— никадәр көч түгелгән! 7. *устар. обл.* ни (мәгънә, хаҗәт, файда). ... (мәгънә, файда) юк; ... ни (мәгънәсе, хаҗәте, файдасы) бар; *что толку жить* (Лермонтов)— яшәүнең ни мәгънәсе бар; *что пользы в этом*— моннан ни файда бар; 8. *устар. разг.* ...-ган (-гән). ...-кан (-кән); *старый дуб, что посажен отцом* (Некрасов)— әти утырткан карт имән; 9. *простореч.* берәр нәрсә (хәл), нәрсә дә булса, ни дә булса; *если что случится, скорей извести*— берәр хәл була калса, тиз үк хәбәр ит; 10. нәрсә, нәрсә бар, нәрсә дисең, ни кирәк; *подойди поближе!— что?*— якынрак кил әле!— нәрсә?— нәрсә дисең? 11. *разг.* нәрсә, нәрсә булыр (булган), ни булыр (булган); *а что, если я опоздаю?*— әгәр соңга калсам, ни булыр? ◇**А что** *разг.*— ник, нигә, ни (нәрсә) булган. **Вот что** *разг.*—1. менә нәрсә; 2. менә нәрсә, эш менә нәрсәдә, эш шунда; *вот что: приходите ко мне обедать*— менә нәрсә: миңа төшке ашка килегез; *сердишь ты меня, вот что* (Достоевский)— минем ачуымны китерәсең, менә нәрсәдә эш. **За чем дело стало?**— эш нәрсәдә, эш нәрсәгә терәлеп калды? **На что (уж)** *разг.*—1. ... булса (м, ң) да, нинди ... булса(м, ң) да, бик; *уж на что Мишка отчаянный, а в этот овраг не прыгнет* (Тургенев)— Мишка нинди батыр булса да, бу ярдан сикерә алмый; 2. *простореч разг.* шундый (шулкадәр, шулчаклы), шундый (шулкадәр, шулчаклы) ...ки; *уж на что красиво!*— шундый матур. **Не за чем**— к. незачем. **Не при чём оставаться**— коры калу. **Ни во что не ставить**— бер тиенгә дә куймау, (берәр нәрсә белән) исәпләшмәү, санашмау. **Ни за чем** *простореч.*— болай гына, бер нинди максатсыз; *ни за чем пришёл*— болай гына килдем. **Ни за что**– 1. *простореч.* бер дә юкка, мәгънәсезгә; чүпкә; *ни за что считать* чүпкә санау; 2. к. низачто. **Ни за что́, ни про что́ и ни за́ что, ни про́ что** *разг.*— к. ни за что 1. **Ни к чему** *в знач. сказ.*— кирәге юк, бернәрсәгә дә кирәге юк, кирәкмәс; *мне эта вещь ни к чему*— бу әйбернең миңа кирәге юк. **Ни с чем** (остаться, уйти и т. п.) *разг.*— бернәрсәсез, буш, коры, теләгенә ирешә алмыйча. **Пока что**— к. пока. **Почти что**— к. почти. **С чего** *разг.*— нигә, нилектән, ни сәбәптән, кайдан алып; *с чего он взял?*— кайдан алып әйтә ул? **Только что**— к. только. **Хоть бы что** *простореч.*— исе(м, н) дә китми, колагына(ма, ңа) да элми(м, сең), мыегы(м, н) да селкенми, уйлап та бирми(м, сең); *его ругают, а ему хоть бы что*— аны тиргиләр, ә аның исе дә китми. **Чего доброго**— к. добрый. **Чем это (не)** ... *разг.*— нәрсәсе белән ул ...; *чем он не учёный?*— нәрсәсе бе-

лән ул галим түгел? **Чего там** — сөйләп торасы да юк. **Что до** *устар.* — к. что касается (касаться сүзендә). **Что ж(е)** — ярый, алайса. **Что за** — нинди; *что за утро!* — нинди иртә! **Что и говорить** — к. говорить. **Что ли** *в знач. ввод. сл. разг.* — ...-мы әллә; *пожар что ли?* — ут чыкканмы әллә? **Что называется** — к. называться. **Что ни попало или что попало** — нәрсә генә эләкмәсен, ни генә булмасын; *что ни попало, тащит все домой* — нәрсә генә эләкмәсен, өенә алып кайта. **Чуть что** *разг.* — берәр хәл (нәрсә) була калса, берәр хәл (нәрсә) килеп чыкса; *чуть что, выезжай домой* — берәр хәл була калса, өйгә кайтырга чык.

**ЧТО** II *союз.*—1. ... дип, ...-ганын, ...-га, ...-гын, ... икәнен; ...ки; *что волки жадны, всякий знает* (Крылов) — бүреләрнең комсызлыгын һәркем белә; *я ответил, что приду сегодня вечером* — мин бүген кич килермен дип җавап бирдем; *я надеюсь, что вы сделаете это* — мин ышанам ки, сез моны эшләрсез, сезнең моны эшләп чыгуыгызга мин ышанам; 2. өчен, ...-ганча, ...-на, ...-га; *я рад, что вы довольны* — сезнең канәгать булуыгызга мин шатмын; *он счастлив, что видит тебя* — ул сезне күрүенә бик шат; 3. шундый ..., шундый итеп ..., шундый ... ки, шундый итеп ... ки; *он сделал так, что все остались довольны* — ул шундый эшләде ки, барысы да канәгать булып калдылар; 4. *нар.-поэт. устар.* кебек, ... -дай, төсле, гүя; *красив, что цветок* — чәчәктәй матур; 5. *(с частицей „ни" и без нее)* һәр ... саен, саен, ... үттеме; *что ни день, крепнит борьба за мир* — тынычлык өчен көрәш көн саен көчәя бара; 6 ...-мы, ...ни ...ни, ...мы, әллә ...мы, ...булса да; *что в городе, что в деревне — все равно* — шәһәрдәме әллә авылдамы — барыбер, шәһәрдә ни, авылда ни — барыбер. ◇ **Не то, что** (бы) — к. тот. **При чем** *союз.* — к. причем. **Только и ..., что** — бары тик (фәкать) ... гына, бары тик (фәкать) кына; *только и живет, что его жизнью* — бары тик аның тормышы белән генә яши. **Что твой** *разг.* — к. что 4.

**ЧТОБ** и **ЧТО'БЫ** *союз.*—1. өчен, ... дип, теләге белән; *я спешу, чтоб не опоздать на поезд* — мин поездга соңга калмас өчен ашыгам; *пришел, чтоб взять книгу* — китап алырга дип килгән; 2. ...сен(сеннәр), ... ны(ын); *кричи, чтоб скорее подавали* — кычкыр, тизрәк китерсеннәр; *он любит, чтобы ему льстили* — ул тәлинкә тотканны ярата; 3. *(в знач. частицы)* ... ыры (...ере); ...сын, ...масын; *чтоб ты лопнул!* — чәнчелгере!; *чтобы этого больше не было!* — бу кабатланмасын! бу кабатланасы булмасын! ◇ **Не то, чтоб(ы)** — к. тот.

**ЧТО'-ЛИБО** *книж. местоим.* — к. что-нибудь.

**ЧТО'-НИБУДЬ** и **ЧТО'-НИБУ'ДЬ** *местоим.* — берәр нәрсә, нәрсә дә булса; *дайте что-нибудь почитать* — укырга берәр нәрсә бирегез.

**ЧТО'-ТО, ЧЕГО'-ТО** и т. д. I *местоим.* — 1. нәрсәдер, нидер; *ему чего-то не хватает* — аңа нәрсәдер җитми; 2. *просторечи.* чамасы, якын, ахрысы, ...-лап; *он мне остался должен что-то рублей сорок* — ул миңа кырык сум чамасы (кырык сумлап) бурычлы булып калды.

**ЧТО'-ТО** II *нарe . разг.*—1. бераз, азрак, аз гына; *мне что-то нездоровится* — минем бераз хәлем китеп тора; 2. ниндер, нәрсәгәдер, нигәдер, ни өчендер; *что-то руки трясутся* — нигәдер куллар калтырый.

**ЧУ** *междом.*— чү! тукта! тукта чү! тик тор! тыңла! *чу! слышится топот* — тукта! аяк тавышлары ишетелә.

**ЧУБ** *м.*— чуб (1. маңгай өстендә генә калдырылган чәч учмасы; 2. *истор.* украин казакларында башны пәке белән кырганнан соң лепкә өстендә бик аз гына калдырылган озын чәч учмасы).

**ЧУБА'РЫЙ** — алмачуар, чуар, бөрчек-бөрчек таплы (ат төсе).

**ЧУБА'ТЫЙ** — тузгыган чәчле.

**ЧУБУ'К** *м.*—1. чыбык, чубук, челем сабы (юллыгы) трубка сабы (юллыгы); 2. *с.-х.* (күчереп утырту өчен) виноград чыбыгы, виноград чыбыкчасы.

**ЧУБУ'ЧНЫЙ** *спец.*— чыбык ...-ы, чубук (челем сабы, трубка сабы) ...-ы; *чубучный мастер* — чубук мастеры.

**ЧУВАШИ'** *м.* — чувашлар (Чувашстан АССРның төп халкы).

**ЧУВА'ШКА** *ж.*— чуваш хатын-кызы.

**ЧУВА'ШСКИЙ** — чуваш ...-ы, чувашлар ...-ы; чувашларга хас; *чувашский язык* — чуваш теле.

**ЧУ'ВСТВЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет —1. *книж.* сизелүчәнлек, тоелучанлык, сизеп (белеп) була торган булу, сизеп беленә торган булу; 2. җенси хиссият, хисле**лек**, тойгылылык; хискә (тойгыга) бирелүчәнлек, дәрткә бирелүчәнлек, гыйш-гашрәткә бирелүчәнлек; хис (тойгы) уятучанлык, дәрт уятучанлык, дәрт кузгатучанлык; 3. *филос.* сизеп белү (үзләштерү) сәләте, сизеп белә (үзләштерә) алучанлык.

**ЧУ'ВСТВЕННЫЙ** —1. *только полн. формы, филос.* сизелүчән, тоелучан, сизеп (белеп) була торган, сизеп беленә торган, сизеп ...-ү; *чувственное восприятие* — сизеп үзләштерү (сизү органнары ярдәмендә үзләштерү); *чувственные предметы* — сизеп беленә торган әйберләр; 2. *только полн. формы, книж.*— хисси, хис (тойгы) ...-ы, җенси; *чувственные удовольствия* — (җенси) тойгы ләззәтләре; 3. *книж.* җенси хискә (тойгыга) бирелүчән, шәһвәткә бирелүчән; *чувственный человек* — җенси хискә (шәһвәткә) бирелүчән кеше; 4. хис (тойгы) уята торган, җенси дәрт уята торган, дәрт кузгатучан; *чувственный взгляд* — җенси дәрт уята торган караш.

**ЧУ'ВСТВИЕ** *ср. книж. устар. теперь ирон.*— к. чувство.

**ШОВИНИ'СТ** *м. полит.* — шовинист, шовинизм тарафдары.

**ШОВИНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *полит.* — шовинистик, шовинист...-ы, шовинизм...-ы, шовинистлык...-ы, шовинистлар...-ы; шовинистларча...; *шовинистическая политика* — шовинистлык политикасы.

**ШОВИНИ'СТКА** *ж.* — шовинистка (шовинист хатын-кыз).

**ШО'ВНЫЙ** *спец.* — жөйләү...-ы, жөйли торган; *шовный материал для перчаток* — перчатка жөйләү материалы.

**ШОК** *м. мед.* — шок (зур психик кичерешләр яки физик имгәнүләр нәтиҗәсендә организм функцияләренең тәмам эштән чыгуы).

**ШОКИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — оялту, уңайсызландыру, уңайсыз хәлгә кую; *их шокировал мой неряшливый вид* — аларны минем алама кыяфәтем уңайсызландырды.

**ШОКИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.* — оялтылу, уңайсызландырылу.

**ШОКОЛА'Д** *м.* — 1. шоколад; *плитка шоколаду* — бер плитка шоколад; 2. шоколад ширбәте (шоколадны сөттә эретеп хәзерләнгән эчемлек).

**ШОКОЛА'ДКА** *ж. разг.* — (бер данә) шоколад конфет, шоколад плиткасы.

**ШОКОЛА'ДНИК** *м. устар.* — какао агачы.

**ШОКОЛА'ДНЫЙ** — 1. шоколад...-ы, шоколад хәзерләү...-ы; *шоколадная фабрика* — шоколад фабрикасы; 2. шоколад..., шоколадлы, шоколадтан ясалган; *шоколадная конфета* — шоколад конфет; *шоколадный торт* — шоколадлы торт; 3. шоколад...-ы, шоколад төсендәге, какао төсендәге, кара көрән; *шоколадный цвет* — шоколад төсе; *шоколадное платье* — шоколад төсендәге күлмәк.

**ШО'МПОЛ** *м.* — шомпол (мылтык көпшәсен чистарту, ә көпшәдән корыла торган мылтыкларда — зарядны тыгызлап тутыру коралы).

**ШО'МПОЛЬНЫЙ** — 1. шомпол...-ы; *шомпольный наконечник* — шомпол очлыгы; 2. көпшәдән корыла торган; *шомпольные ружья* — көпшәдән корыла торган мылтыклар.

**ШО'ПОТ** *м.* — 1. пышылдау, пышылдау тавышы, пышылдашу, пышылдап сөйләү, пышылдап сөйләшү; *между игроками поднялся шопот* (Пушкин) — уйнаучылар пышылдаша башладылар; 2. *перен. поэт.* кыштырдау; чылтырау; *шопот ручья* — чишмәнең чылтыравы.

**ШО'ПОТНЫЙ** *лингв.* — пышылдаулы, пышылдап әйтелә торган; *шопотные звуки* — пышылдап әйтелә торган авазлар.

**ШО'ПОТОМ** *нареч.* — пышылдап; *говорить шопотом* — пышылдап сөйләү.

**ШО'РКА** *спец.* — к. шлея 3.

**ШО'РКАТЬ** *несов. обл.* — кыштырдау, шытырдау; кыштырдату, шытырдату.

**ШО'РНИК** *м.* — шорник, сбруй ясаучы.

**ШО'РНЫЙ** — 1. каеш..., каештан ясалган; *шорная упряжь* — каеш сбруй; 2. сбруй...-ы, каеш сбруй...-ы; *шорная мастерская* — сбруй мастерское.

**ШО'РОХ** *м.* — кыштырдау, шытырдау.

**ШО'РСТКА** *ж. мн.* нет — 1. *разг.* к. шерсть 1; 2. *обл.* к. шерстинка.

**ШО'РЦЫ** *мн.* — шор халкы, шорлар (төрки телдә сөйләшүчеләр төркеменә кергән Төньяк Алтайда яшәүче халык).

**ШО'РЫ** *ед.* нет — 1. каеш сбруй (дугадан, камыттан башкалары); 2. йөгән күзлеге (өң кәк атка як-якка каранырга комачаулау өчен); 3. *перен. книж.* чикләнгәнлек, пәрдә, киртә (берәр нәрсәне дөрес аңларга комачаулык итүче киртә); *классовые шоры буржуазных историков* — буржуаз тарихчыларның сыйнфый чикләнгәнлекләре.

**ШОССЕ'** *ср. нескл.* — шоссе (вак таш жәелгән юл; гомумән, асфальт яки таш җәелгән юл).

**ШОССЕ'ЙНЫЙ** — 1. шоссе...; *шоссейные дороги* — шоссе юллар; 2. шоссе юл салу...-ы; шоссе салу...-ы; *шоссейные работы* — шоссе юл салу эшләре.

**ШОССИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.* — шоссе салу, шоссе юл салу, шоссе үткәрү; (юлны) шоссега әйләндерү.

**ШОССИ'РОВАТЬСЯ** *несов. спец. страд.* — шоссе салыну, шоссе юл салыну шоссе үткәрелү; шоссега әйләндерелү.

**ШОТЛА'НДКА** *ж.* — 1. шотландияле хатын, шотландияле кыз, шотландияле хатын-кыз; 2. шотландка (эре шакмаклы чуар тукыма).

**ШОТЛА'НДСКИЙ** — Шотландия...-ы шотландияле...-ы, шотландиялеләр...-ы; шотландиялеләргә хас; *шотландская песня* — шотландиялеләр җыры.

**ШОТЛА'НДЦЫ** *мн.* (*ед.* шотландец) — шотландиялеләр, Шотландия халкы.

**ШОФЁР** *м.* — шофёр (автомобиль йөртүче).

**ШОФЁРСКИЙ** — шофёр...-ы, шофёрлар...-ы, шофёрлык...-ы, шофёрларга хас; *шофёрские права* — шофёрлык хокуклары.

**ШОФЁРСТВО** *ср. мн.* нет — шофёрлык, шофёр профессиясе.

**ШПА'ГА** *ж.* — шпага (очлы кылыч). ◇ **Продать шпагу** *книж. устар. перен.* — хыянәт итү; дошман ягына чыгу, дошманга сатылу. **Скрестить шпаги** *книж.* — 1. бергәбер сугышу (сугышта, дуэльдә); 2. *перен* сүз көрәштерә башлау, бәхәсләшә башлау.

**ШПАГА'Т** *м.* — шпагат.

**ШПАГОГЛОТА'ТЕЛЬ** *м.*— шпага йотучы, кылыч йотучы (шпаганы йоткан яки тамагына тыккан булып фокус күрсәтүче кеше).

**ШПА'ЖНИК** *м. бот.*—шпажник (сугансыман кыр үсемлеге).

**ШПА'ЖНЫЙ** — шпага ...-ы; *шпажный эфес* шпага сабы.

**ШПАКЛЕВА'ТЬ** *несов.*— 1. шпаклёвкалау, (ярыкларын) шпаклёвка белән сылау; *шпаклевать двери* — ишекләрне шпаклёвкалау; 2. *сапож.* шпаклёвкалау, җөе беленмәслек итеп тегү.

**ШПАКЛЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — 1. шпаклёвкалану, (ярыклары) шпаклёвка белән сылану; 2. *сапож.* шпаклёвкалану, җөе беленмәслек итеп тегелү.

**ШПАКЛЁВКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— 1. к. шпаклевать; 2. *маляр.* шпаклёвка, замазка.

**ШПАКЛЁВОЧНЫЙ** *спец.* — шпаклёвка ...-ы, шпаклёвкалау ...-ы; *шпаклёвочные материалы* — шпаклёвка материаллары.

**ШПАКЛЁВЩИК** *м.*— шпаклёвщик, шпаклёвкалаучы.

**ШПАЛЕ'РА** *ж.*— шпалер (1. *только мн. устар.* к. обои; 2 берәр кеше яки берәр нәрсә үткәндә юлга ике яклап тезелгән гаскәр; 3. *спец.* юл буенча ике яклап утыртылган агачлар, куаклар; 4. *спец.* үсемлекләргә үрелеп үсү яки агачка билгеле форма биреп үстерү өчен аларның ботаклары бәйләп куела торган рәшәткә).

**ШПАЛЕ'РНИК** *м. спец.* — юл буенча ике яклап утыртылган агачлар; *персиковый шпалерник* — юл буенча ике яклап утыртылган шапталы агачлары.

**ШПАЛОПРОПИ'ТОЧНЫЙ** *тех.*— шпалга антисептик матдә сеңдерү ...-ы; *шпалопропиточный за од* — шпалга антисептик матдә сеңдерү заводы.

**ШПА'ЛЫ** *мн.*— шпаллар, шпал (тимер юл полотносында рельслар астына аркылы салына торган агач, тимер-бетон яки металл борыс).

**ШПАНА'** *ж. мн.* нет —1. *устар.* шпана, төрмәгә ябылган кеше (ләр); 2. *простореч. вульг.* шпана, жулик(лар), хулиганнар.

**ШПАНГО'УТ** *м. мор. ав.*— шпангоут (судно корпусында, самолёт фюзеляжында конструкциягә ныклык бирү хезмәтен үтәүче аркылы кабырга, аркылы борыс).

**ШПА'НДЫРЬ** *м. сапож.*— шпандырь (итекчеләрдә тегеләә торган әйберне аякка тарттырып кую каешы).

**ШПА'НКА** *ж.* шпанка (1. *зоол.* яшькелт коңгыз; 2. *с.-х.* чиянең бер төре; 3. *с.-х.* сарык токымы).

**ШПАРГА'ЛИТЬ** *несов. школьн.*— шпаргалкадан файдаланып җавап бирү, шпаргалкадан күчереп язу.

**ШПАРГА'ЛКА** *ж. школьн.*— шпаргалка (укучыларның язма эш башкарганда яки җавап бирү вакытында укытучылардан яшереп файдалану өчен алдан хәзерләп куйган язулары).

**ШПАРГА'ЛОЧНИК** *м.*— шпаргалкачы, шпаргалкадан файдаланучы.

**ШПА'РИТЬ** *несов.*— 1. *разг.* пешекләү; 2. *простореч. вульг.* тиз-тиз берәр нәрсә эшләү (йөгерү, бару, элдертү, сөйләү, уку һ. б.); *шпарить по улице* — урам буйлап чабу, урам буйлап элдертү.

**ШПА'РИТЬСЯ** *несов. разг.*— 1. кайнар су түгү, кайнар су белән пешерү (мәсәлән, кулны, аякны); 2. *страд.* пешекләнү.

**ШПАТ** I *м. мин.*— шпат (минерал).

**ШПАТ** II *м. ветер.*— шпат (атларның аяк сөягендә була торган хроник ялкынсыну).

**ШПА'ТЕЛЬ** *м.*— шпатель (1. *маляр.* шпаклёвка калагы; 2. *живоп.* палитра өстенә салып төрле майлы буяуларны кушу һәм буяуны киндергә сылау өчен кулланыла торган бик юка һәм сыгылма корычтан эшләнгән үтмәс пычак; 3. *мед* авыз бушлыгын тикшергәндә телне басып тору өчен эшләнгән калак).

**ШПА'ХТЕЛЬ** *м. спец.*— к. шпатель 1, 2.

**ШПА'ЦИЯ** *ж.*— шпация (1. *тип.* хәрефләр арасына ачык урын калдыру өчен кыстырып куела торган материал; 2. *мор. ав.* шпангоутлар арасы).

**ШПЕК** *м. мн.* нет — к. шпик I.

**ШПЕНЁК** *м.*— 1. к. шпень; 2. прәжкә эләктергече, прәжкә теле (мәсәлән, бил каешында, тасмада).

**ШПЕНЬ** *м. обл.*— к. шпинь.

**ШПИГОВА'ТЬ** *несов.*— 1. шпиклау, дуңгыз мае тутыру (мәсәлән, кош, куян итенә); *шпиговать зайца свиным салом* — куян итен дуңгыз мае белән шпиклау; 2. *перен. разг.* төшендерү, аңлату; 3. *разг. фам.* к. шпынять.

**ШПИГОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— шпиклану, дуңгыз мае тутырылу.

**ШПИК** I *м.*— чи дуңгыз мае.

**ШПИК** II *м. разг. презрит.* — шпик, шымчы.

**ШПИ'ЛЕЧНЫЙ** — шпилька ...-ы, шпилька ясау ...-ы; *шпилечное производство* — шпилька ясау производствосы.

**ШПИЛЬ** *м.*—шпиль (1. *спец.* озын кадак; 2. бина түбәләрендә очлаеп киткән өскорма; 3. *мор.* судноларда якорь күтәртү чыгыры).

**ШПИ'ЛЬКА** *ж.*—1. шпилька (а. хатынкызларның чәч кыстыру әйбере; б. хатынкыз эшләпәсе булавкасы; в. *сапож.* итекчеләр кадагы, ике башлы кадак; г. *тех.* машина частьларын винтлап берләштерә торган деталь); 2. *перен.* чәнчеп әйтелгән сүз, чәнчүле сүз.

**ШПИ'ЛЬМАН** *м. истор.*— шпильман (урта гасырларда Германиядә илгизәр җырчымузыкант).

**ШПИНА'Т** *м.*— шпинат (яшелчә).

**ШПИНА'ТНЫЙ** — 1. шпинат ...-ы, шпинаттан хәзерләнгән; *шпинатный соус* — шпинат соусы; 2. *с.-х.* шпинат ..., ашарга ярый торган; *шпинатные растения* — шпинат үсемлекләр (мәсәлән, балтырган, кузгалак, кычыткан һ. б.).

**ШПИНГАЛЕ'Т** *м.*— ишек эшермәсе, тәрәзә эшермәсе, шудырмалы бик.

**ШПИ'НДЕЛЬ** *тех.*— шпиндель (1. станокның төп валы; 2. эрләү машинасы орчыгы; 3. бирәр нәрсәнең, мәсәлән, катушканың, судно шпиленең күчәре).

**ШПИНЁК** *м.*— к. шпенёк.

**ШПИНЬ** *ж. обл., спец.*— к. шип I во 2 знач.

**ШПИО'Н** *м.*, **ШПИО'НКА** *ж.*— шпион; шымчы.

**ШПИОНА'Ж** *м. мн.* нет — шпионаж, шпионлык; шымчылык.

**ШПИО'НИТЬ** *несов.*— шпионаж белән шөгыльләнү, шпионлык итү; шымчылык итү.

**ШПИО'НСКИЙ** — шпион ...-ы, шпионнар...-ы; шпионнарга хас; шпионаж ...-ы, шпионлык ...-ы; шымчы...-ы, шымчылык ...-ы; *шпионская организация* — шпионнар оешмасы.

**ШПИО'НСТВО** *ср. мн.* нет — к. шпионаж.

**ШПИЦ** I *м.*— к. шпиль 2.

**ШПИЦ** II *м.*— шпиц (йонлач кечкенә эт).

**ШПИЦРУ'ТЕН** *м. истор.*— шпицрутен (җәзага тартылган солдатларны кыйнау өчен озын сыгылмалы чыбык яки таяк).

**ШПЛИНТ** *м. тех.*— шплинт (аерым детальләрне беркетү өчен эшләнгән тимер чыбык).

**ШПОН** *м.*, **ШПО'НА** *ж.*—шпон (1. *тип.* юллар арасын киңәйтү өчен куела торган юка металл линейка; 2. *тех.* бер катлы фанер).

**ШПО'НКА** *ж. тех.*— чөй, шпонка (мәсәлән, машина шкивын валга беркеткәндә).

**ШПО'НОЧНЫЙ** *тех.*— чөй ...-ы; шпонка...-ы; *шпоночное отверстие* — чөй тишеге.

**ШПО'РА** *ж.*—1. шпор (җайдакларда атны әйдәү өчен итек үкчәсенә беркетелгән кечкенә тәгәрмәчле тимер); 2. типке (этәч аягының арткы бармагы); 3. *зоол.* к. шпорца.

**ШПО'РЕ'Ц** *м. бот.* — касә орысы; таҗчык орысы (үсемлекләрдә).

**ШПО'РИТЬ** *несов.*— шпорлау, шпорлап әйдәү; *шпорить лошадь* — атны шпорлау.

**ШПО'РНИК** I *м. бот.*— испәрәк, зәңгәр чәчәк (чүп үлән).

**ШПО'РНИК** II *м. зоол.*— шпорник (тависка охшаган кош).

**ШПО'РЦА** *ж. зоол.*— мөгез үсенте, мөгез чыгынты (кайбер кошларның канатларында).

**ШПРИНТО'В** *м. мор.*— шпринтов (җилкәнне киереп җәю өчен мачтага беркетелгән колга).

**ШПРИНЦЕВА'ТЬ, ШПРИНЦЕВА'ТЬСЯ, ШПРИНЦО'ВКА** — к. спринцевать һ. б.

**ШПРИЦ** *м.*— шприц (тәнгә сыек дару җибәрү коралы).

**ШПРИЦЕВА'ТЬ** *несов. тех.*— шприцлау (резин катнашмасын махсус тишек аша кысып чыгарып куыш эчле резин әйберләр хәзерләү).

**ШПРИЦЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд. тех.* — шприцлану.

**ШПРО'ТИНА** *ж. разг. фам.*— к. шпроты.

**ШПРО'ТНЫЙ** — шпрот ...-ы, шпрот хәзерләү ...-ы; *шпротная коробка* — шпрот тартмасы; *шпротный цех* — шпрот хәзерләү цехы.

**ШПРО'ТЫ** *мн.* — шпрот (майда консервланган килька балыгы).

**ШПУ'ЛЬКА** *ж.*— шүре, кәтүк (тегү, туку машиналарында җеп чорнау өчен).

**ШПУ'ЛЬНИК** *м.*, **ШПУ'ЛЬНИЦА** *ж. спец.*— шүрече, шүрегә җеп чорнаучы, кәтүкче, кәтүккә җеп чорнаучы.

**ШПУ'ЛЯ** *ж. спец.*— к. шпулька.

**ШПУНТ** *м. плотн.*— шпунт (1. янәшәсендәге такта яки борыстагы ырмау белән беркетү өчен тактада яки борыста ясалган озынча чыгынты; 2. *тех.* шпунтлап ясалган стена).

**ШПУНТОВА'ЛЬНЫЙ** *плотн.*— шпунт ясау...-ы, шпунтлау...-ы; *шпунтовальный станок* — шпунт ясау станогы.

**ШПУНТО'ВАННЫЙ** *плотн.*— 1. *страд.* шпунтланган, шпунт ясалган; 2. шпунтлы; *шпунтованные доски* — шпунтлы такталар.

**ШПУНТОВА'ТЬ** *несов. плотн.*— шпунтлау, шпунт ясау; *шпунтовать доску* — тактаны шпунтлау.

**ШПУНТОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. плотн.*— шпунтлану, шпунт ясалу.

**ШПУНТОВО'Й** *плотн.*— 1. шпунтлы; *шпунтовая доска* — шпунтлы такта; 2. шпунтлы такталардан ясалган; *шпунтовая стена* — шпунтлы такталардан ясалган стена.

**ШПУНТУ'БЕЛЬ** *м. плотн.*— шпунтубель, ырмау ясау ышкысы, ырмау ую ышкысы.

**ШПУР** *м.*— шпур (1. *горн.* шартлатып ваттыру максаты белән тау токымнарына бораулап ясалган тишек; 2. *тех.* шахта миченде эреткәннән соң сыек продуктларны агызыр өчен эшләнгән тишек, авыз, юллык).

**ШПУРОВО'Й** *горн. тех.*— шпур...-ы; *шпуровая скважина* — шпур скважинасы; *шпуровое отверстие* — шпур тишеге.

**ШПЫНЬ** *м. обл.*— 1. *обл.* к. шпинь; 2. *старин.* көлдерүче, мәзәкче кеше.

**ШПЫНЯ'ТЬ** *несов.*— 1. *простореч.* чәнчү, кадау; *шпынять булавкой* — булавка белән чәнчү; 2. *перен. разг. фам.* (чәнечкеле сүз әйтеп) кимсетү, мыскыл итү.

**ШРАМ** *м.*— яра эзе, яра урыны; *шрам на лице* — йөздәге яра эзе.

**ШРАПНЕ'ЛЬ** *ж.*— 1. шрапнель (эченә пулялар тутырылган һәм һавада ярыла торган артиллерия снаряды); 2. *перен. простореч. фам. шутл.* арпа ярмасы.

**ШРАПНЕ'ЛЬНЫЙ** — шрапнель ..., шрапнель ...-ы; *шрапнельный снаряд* — шрапнель снаряд; *шрапнельный огонь* — шрапнель уты (шрапнель снарядлар белән ату).

**ШРЕ'ДЕР** *м. с.-х.*— шредер (кукуруз сабакларын турау машинасы).

**ШРЕДЕРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. с.-х.*— шредерлау, шредерда турау, шредерда ваклау; *шредеровать кукурузу* — кукурузны шредерлау.

**ШРЕДЕРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.*— шредерлану, шредерда туралу, шредерда ваклану.

**ШРИФТ** *м.*— шрифт, хәреф (китап басу хәрефе); *латинский шрифт* — латин шрифты; *мелкий шрифт* — вак шрифт.

**ШТАБ** *м.*—штаб (1. командованиенең гаскәрләр белән житәкчелек итү органы; 2. *перен.* берәр нәрсәнең житәкче органы).

**ШТАБЕЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец* — штабельгә өю, әрдәнәгә өю, өемгә өю.

**ШТАБЕЛИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— штабельгә өелү, өемгә өелү.

**ШТА'БЕЛЬ** *м.*— штабель; әрдәнә, өем; *штабель дров* — утын әрдәнәсе.

**ШТАБ-КВАРТИ'РА** *ж.*— штаб-квартира (1. *воен.* штаб урнашкан урын; 2. *перен.* берәр нәрсәнең төп пункты).

**ШТАБНО'Й** I — штаб ...-ы; *штабной офицер* — штаб офицеры; *штабное помещение* — штаб бинасы.

**ШТАБНО'Й** II *в знач. сущ.*— штабта хезмәт итүче.

**ШТАБ-ОФИЦЕ'Р** *м. дореeол., загр.*— штаб-офицер (полковник, подполковник һәм майор дәрәҗәсендәге офицерларга бирелгән исем).

**ШТАБ-ОФИЦЕ'РСКИЙ** *дореeол. загр.*— штаб-офицер ...-ы; штаб-офицерларга хас; *штаб-офицерский чин* — штаб-офицер чины.

**ШТАБ-РО'ТМИСТР** *м. дореeол.*—штаб-ротмистр (кавалерия һәм жандармериядәге офицер чины, җәяүле гаскәрдәге штабс-капитанга туры килә).

**ШТАБС-КАПИТА'Н** *м. дореeол.* — штабс-капитан (патша армиясендә — җәяүле гаскәрдә, артиллериядә һ. б. поручик һәм капитан арасындагы чин).

**ШТАБС-КАПИТА'НСКИЙ** *дореeол.* — штабс-капитан ...-ы; штабс-капитаннарга хас; *штабс-капитанские погоны* — штабс-капитан погоннары.

**ШТАГ** *м. мор.*— штаг (мачтаны артка авудан саклаучы канат).

**ШТАЛМЕ'ЙСТЕР** *м. дореeол.*— шталмейстер (патша Россиясендә сарай түрәләренең бер чины).

**ШТАМБ** *м. бот., с.-х.*— кәүсә, агач кәүсәсе (тамырыннан ботакларына кадәр).

**ШТА'МБОВЫЙ** *бот., с-х.*— ботак җибәрми торган, ботаксыз үсә торган; *штамбовые деревья* — ботак җибәрми торган агачлар.

**ШТАМП** *м.*— штамп (1. штамповка юлы белән төрле детальләр, әйберләр ясау өчен металлдан эшләнгән калып; 2. *тех.* күннән аяк киеменең төрле өлешләрен кисү машинасы; 3. берәр учреждениенең исеме язылган, гадәттә эш кәгазенең сул якгагы югары өлешенә басыла торган дүрт почмаклы мөһер; 4. *перен. неодобр.* к. шаблон 2.)

**ШТАМПОВА'ЛЬНЫЙ** — штамповка ...-ы, штамповкалау ...-ы; *штамповальный станок* — штамповка станогы.

**ШТАМПО'ВАННЫЙ** — 1. *страд.* штамп басылган, штампланган, штамп сугылган; 2. *страд.* штамп белән ясалган, штамповкаланган, штамповка юлы белән ясалган; 3. *перен. неодобр.* к шаблонный 2.

**ШТАМПОВА'ТЬ** *несов.* — 1. штамповкалау; штамплап детальләр ясау; 2. *канц.* штамплау, штамп сугу, штамп басу; 3. *перен. неодобр.* әзер өлгеләр буенча эшләү; әзер калып буенча эшләү.

**ШТАМПОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— 1. штамповкалану, штамповка юлы белән ясалу; 2. *канц.* штамп сугылу, штамп басылу.

**ШТАМПО'ВЩИК** *м.*, **ШТАМПО'ВЩИЦА** *ж.*— штамповкачы, штамповкалаучы.

**ШТА'НГА** *ж.*— штанга (очларына металл шар яки диск урнаштырыла торган металл күчәр); *спортивная штанга* — спорт штангасы; *буровая штанга* — бораулау штангасы (җир бораулау коралы).

**ШТАНГЕНЦИ'РКУЛЬ** *м. спец.*— штангенциркуль (әйберләрнең калынлыгын һәм тишекләрнең киңлеген үлчәү инструменты).

**ШТАНГИ'СТ** *м.*, **ШТАНГИ'СТКА** *ж. спорт.*— штангачы (штанга белән төрле күнегүләр ясаучы спорт остасы).

**ШТА'НГОВЫЙ** *горн.*— штангалы, штанга белән ...; *штанговое бурение* — штанга белән бораулау.

**ШТАНДА'РТ** *м. устар.*— байрак, флаг, штандарт.

**ШТАНДА'РТНЫЙ** *устар.*— байрак ...-ы, флаг...-ы, штандарт ...-ы; *штандартное древко* — байрак сабы.

**ШТАНИ'НА** *ж. разг.*— балак (штан балагы, чалбар балагы).

**ШТАНИ'ШКИ** *ед.* нет, *разг.*— штан; кечкенә штан; кыска штан.

**ШТАННО'Й** *разг.*—штан...-ы; *штанные пуговицы* — штан төймәләре.

**ШТАНЫ'** *ед.* нет, *разг.*— чалбар, штан. ◇ **Пифагоровы штаны** *школьн. шутл.* — Пифагор чалбары (Пифагор теоремасына шаяртып бирелгән исем).

**ШТА'ПЕЛЬ** *м. спец.*— штапель (1. бер төрле бөдрәле йоннардан тора торган йон учмасы; 2. ясалма тукыманың бер төре).

**ШТАТ** I *м.*— штат (1. Австралиядә һәм кайбер Америка дәүләтләрендә административ-территориаль берәмлек; 2. *истор. только. мн.* Нидерландиядә һәм Франциядә аерым сословие вәкилләреннән торган учреждениеләргә бирелгән исем).

**ШТАТ** II *м.*— штат (1. берәр учреждениедә эшләүчеләрнең даими составы; *сокращение штатов* — штатларны кыскарту; 2. берәр учреждениедә эш урыннарының һәм эшләүчеләрнең саны, аларның функциясе турындагы положение; *утвердить штаты* — штатларны раслау).

**ШТАТГА'ЛЬТЕР** *м. истор.*— штатгальтер (халкы немец телендә сөйләшүче кайбер илләрдә өлкә башлыгы, өлкә белән идарә итүче).

**ШТАТИ'В** *м.*— штатив (1. *спец.* приборлар куя торган җайланма; 2. фотография аппараты беркетелә торган җыелма өчаяк)

**ШТА'ТНЫЙ** — штаттагы, штатта торучы; *штатный служащий* — штаттагы хезмәткәр.

**ШТА'ТСКИЙ** I — штатский, гражданский; *штатский человек* — штатский кеше.

**ШТА'ТСКИЙ** II в *знач. сущ.*— штатский кеше, гражданский кеше.

**ШТА'ТСКОЕ** *ср. в знач. сущ.*— штатский кием, гражданский кием.

**ШТЕ'ВЕНЬ** *м. мор.*— штевень (кораб койрыгының яки борынының нигезен тәшкил итүче калын вертикаль борыс).

**ШТЕЙГЕР** *м.* — штейгер (рудниктагы эшләрне алып баручы мастер).

**ШТЕЙН** *м.*— штейн (төсле металлар эретүдән хасил булган продукт).

**ШТЕМПЕЛЕВА'ТЬ** *несов.*— штемпельләү, штемпель басу, штемпель сугу.

**ШТЕМПЕЛЕВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— штемпельләнү, штемпель басылу, штемпель сугылу.

**ШТЕ'МПЕЛЬ** *м.*— штемпель.

**ШТЕ'МПЕЛЬНЫЙ** — 1. штемпель ...-ы; *штемпельная краска* — штемпель буявы; 2. штемпельле; *штемпельный конверт* — штемпельле конверт (өстенә маркасы басылган конверт).

**ШТЕ'ПСЕЛЬ** *м.*— штепсель (электр әсбабы).

**ШТЕ'ПСЕЛЬНЫЙ**—штепсель ...-ы, штепсель өчен эшләнгән; *штепсельная вилка*— штепсель чәнечкесе.

**ШТИБЛЕ'ТЫ** *мн.*— штиблет (1. *устар.* төймәләнә торган гетр — ботинка өстеннән киелә торган җылы куныч; 2. ирләр ботинкасы).

**ШТИЛЕВА'ТЬ** *несов. мор.* — хәрәкәтсез тору, кузгалмый тору (диңгездә җил юклыктан).

**ШТИЛЕВО'Й** *мор.*— штиль ...-ы; бөтенләй җилсез; *штилевой период* — штиль вакыты.

**ШТИЛЬ** *м.*— штиль, җилсезлек (диңгездә, елгада, күлдә).

**ШТИ'ЛЬНЫЙ** *мор.*— к. штилевой.

**ШТИФТ** *м. спец.*— штифт (башсыз кадак).

**ШТИФТОВО'Й** — штифтлы, штифт белән беркетелгән.

**ШТИ'ХЕЛЬ** *м.*— штихель (металлга һәм агачка чокып рәсем ясау коралы).

**ШТОК** *м.* — шток (1. *горн.* бик чикләнгән мәйданны алып торучы казылма байлык чыганагы; 2. *тех.* пар цилиндры пешкәген шатун белән тоташтыручы кендек; 3. *мор.* якорьның өске өлешендә аркылы борыс).

**ШТОКРО'ЗА** *ж.*— штокроза, гөлхәйре (гөл).

**ШТО'ЛЬНЯ** *ж. горн.*— штольня.

**ШТО'ПАЛЬНЫЙ** — тупчу ...-ы, тупчый торган; *штопальные иглы* —тупчу инәләре.

**ШТО'ПАЛЬЩИЦА** *ж.*— тупчучы.

**ШТО'ПАНЫЙ** —тупчылган, тупчып ямалган; *штопаные чулки* — тупчылган оеклар.

**ШТО'ПАТЬ** *несов.*— тупчу, тупчып ямау.

**ШТО'ПАТЬСЯ** *несов. страд.*— тупчылу, тупчып ямалу.

**ШТО'ПКА** *ж.*— 1. *только ед.* к. штопать; 2. *только ед.* тупчу җебе, тупчып ямау җебе; 3. тупчылган урын, тупчып ямалган урын.

**ШТО'ПОР** *м.*— штопор (1. бөке суыргыч; 2. *ав.* иң югары пилотаж фигурасы — винт сызыгы буенча самолётның түбәнгә таба бик тиз төшүе).

**ШТО'ПОРИТЬ** *несов. ав.*— штопор ясау, штопор ясап төшү.

**ШТО'ПОРНЫЙ** — штопор ...-ы, штопордагы; *штопорное положение* — штопордагы хәл.

**ШТО'РА** *ж.*— штор, пәрдә, тәрәзә пәрдәсе.

**ШТО'РКА** *ж.*— 1. *разг.* к. штора; 2. *спец.* япкыч, пәрдәчек; *шторка в фотографическом аппарате*— фотография аппаратының япкычы.

**ШТОРМ** *м.*— шторм, давыл (диңгездә, һавада); *поднялся шторм* — шторм кузгалды.

**ШТОРМИ'ТЬ** *несов. безл. мор.*— штормлы булу, давыллы булып тору; *с утра штормило* — иртәдән бирле давыллы булып торды.

**ШТОРМОВА'ТЬ** *несов. мор.*— штормга бирешмәү, давылга бирешмәү; штормны җиңеп бару, давылны җиңеп бару; *корабль штормовал целые сутки* — кораб тәүлек буена штормга бирешмәде.

**ШТОРМОВО'Й** — 1. шторм ...-ы, давыл ...-ы; *штормовой сигнал* — шторм сигналы; 2. штормлы, давыллы; *штормовой ветер*— давыллы җил.

**ШТОРМТРА'П** *м. мор.*— штормтрап (кораб бик нык чайкалган вакытта файдалану өчен баудан эшләнгән баскыч).

**ШТО'РНЫЙ** — 1. штор ...-ы; пәрдә ...-ы, тәрәзә пәрдәсе ...-ы; *шторные шнуры* — штор баулары; 2. япкыч ...-ы; *шторная затворка* — япкыч бигe (фотография аппаратында).

**ШТОФ** I *м. устар.*— штоф (1. чиләкнең уннан бер өлешенә туры килә торган эчемлек, аракы үлчәве; 2. шул микъдардагы бер шешә аракы).

**ШТОФ** II *м.*—штоф (өй җиһазларын тышлау, гардин, ишек чаршавы ясау өчен кулланыла торган йон яки ефәк тукыма).

**ШТО'ФНЫЙ** I *устар.*— 1. штоф сыешлы бер штоф сыешлы; *штофная бутыль*—бер штоф сыешлы шешә; 2. эчемлек ...-ы, аракы ...-ы; *штофные лавочки* — эчемлек кибетләре.

**ШТО'ФНЫЙ** II — 1. штофтан тегелгән; штоф белән тышланган; *штофные портьеры* — штофтан тегелгән ишек чаршаулары; *штофная мебель* —штоф белән тышланган мебель; 2. *спец.* штоф ...-ы, штоф тукуга китә торган, штоф тукуда кулланыла торган; *штофная шерсть* —штоф тукуда кулланыла торган йон.

**ШТРАФ** *м.*—штраф; *наложить штраф*— штраф салу; *заплатить штраф* — штраф түләү.

**ШТРАФНО'Й**—1. штраф ...-ы; *штрафные деньги* — штраф акчасы; 2. штраф ...-ы, шелтә ...-ы; *штрафной журнал* (*доревол.*)—штраф журналы (укучыларның тәртипсезлекләрен язып бару журналы); *штрафной удар* (*спорт.*) — штраф тубы (футбол уенында берәр кагыйдәне бозган өчен тупны капкага якыннан тибеп озатырга рөхсәт итү).

**ШТРАФО'ВАННЫЙ** I — штраф салынган.

**ШТРАФО'ВАННЫЙ** II *в знач. сущ. доревол.*— штрафка эләккән кеше, шелтәгә эләккән кеше, җәзага тартылган кеше (хезмәте буенча берәр җәзага тартылган кеше турында).

**ШТРАФОВА'ТЬ** *несов.*— штраф салу, штраф түләтү.

**ШТРАФОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*—штраф салыну, штраф түләтелү.

**ШТРЕЙКБРЕ'ХЕР** *м.*— штрейкбрехер (капиталистик илләрдә забастовка вакытында эш ташламыйча, хуҗаларга ялланып, эшчеләр интересына хыянәт итүче кеше).

**ШТРЕК** *м. горн.*— штрек (рудникларда, шахталарда казылма байлык катлавы буенча ясалган һәм җир өстенә чыкмый торган юл).

**ШТРИ'ПКА** *ж.*—штрипка (башмак аяктан төшмәсен өчен аны астан әйләндереп алып балак очына каптырыла торган тасма); *брюки со штрипками* — штрипкалы чалбар.

**ШТРИХ** *м.*— 1. штрих, нечкә сызык; *штрих на бумаге* — кәгазьгә төшерелгән нечкә сызык; 2. *перен.* штрих, үзенчәлекле як, үзенчәлекле сыйфат; *добавить еще один штрих к характеристике* — характеристикага тагын бер штрих (үзенчәлекле сыйфатны) өстәргә кирәк.

**ШТРИХОВА'ТЬ** *несов.*—штрихлау, нечкә сызыклар сызу.

**ШТРИХОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*—штрихлану, нечкә сызыклар сызылу.

**ШТРИХО'ВКА** *ж.*— 1. *только ед.* к. штриховать; 2. штриховка, штрихлар, нечкә сызыклар; *нанести густую штриховку* — куе итеп нечкә сызыклар сызу.

**ШТРИХОВО'Й** *спец.*— штрихлар белән эшләнгән (башкарылган), нечкә сызыклар белән эшләнгән (башкарылган); *штриховой рисунок* — штрихлар белән эшләнгән рәсем.

**ШТУДИ'РОВАТЬ** *несов.* — өйрәнү, җентекләп өйрәнү; *штудировать физику* — физиканы өйрәнү.

**ШТУДИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— өйрәнелү, җентекләп өйрәнелү.

**ШТУ'КА** *ж.*— 1. (*о ткани*) оч; *штука сукна* — бер оч постау; 2. данә, бер данә; *десять штук яблок*—ун данә алма; 3. *разг. фам.* әйбер, нәрсә; *купил хорошую штуку* — яхшы әйбер сатып алдым; 4. *разг. фам.* кем; *и по роже его видно, что он за штука* (Чехов) — аның кем икәнлеге чыраеннан ук күренеп тора; 5. *разг. фам.* хәл, эш, вакыйга; әкәмәт, кыланыш; хәйлә, уйдырма; *это всё штуки* — болар барысы да уйдырма; 6. *только ед. разг. фам.* эш, мәсьәлә, нәрсә; *вся штука в том, Захар Иванович, что человек слаб* (Салтыков-Щедрин) — бөтен эш, Захар Иванович, кешенең йомшаклыгында.

**ШТУКА'РИТЬ** *несов. разг. фам.*— хәйләләр кору, әкәмәтләр ясау, әкәмәтләр кору.

**ШТУКА'РСТВО** *ср. разг. фам.*— хәйлә кору; әкәмәтләр кору.

**ШТУКА'РЬ** *м. разг. фам.*— хәйләләр коручы, әкәмәтләр коручы.

**ШТУКАТУ'Р** *м.*— штукатур, штукатурчы.

**ШТУКАТУ'РИТЬ** *несов.*— штукатурлау, штукатурка сылау.

**ШТУКАТУ'РИТЬСЯ** *несов.*—1. *страд.* штукатурлану; 2. *разг. шутл.* буяну (мәсәлән, пудра, кершән белән).

**ШТУКАТУ'РКА** *ж. мн.* нет — 1. к. штукатурить; 2. штукатурка (стенага, түшәмгә сылау өчен хәзерләнгән масса).

**ШТУКАТУ'РНЫЙ** — штукатурлау ...-ы, штукатурка ...-ы; *штукатурный мастер* — штукатурлау остасы.

**ШТУКОВА'ТЬ** *несов. порт.*— җөе беленмәслек итеп тегү, җөе беленмәслек итеп ямау; *штуковать дырку на брюках* —чалбар ертыгын җөе беленмәслек итеп ямау.

**ШТУКОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— җөе беленмәслек итеп тегелү, җөе беленмәслек итеп ямалу.

**ШТУКО'ВИНА** *ж. простореч. фам.*— к. штука 3, 4, 5, 6.

**ШТУКО'ВКА** *ж. порт.*— 1. *только ед.* к. штуковать; 2. җөе беленмәслек итеп тегелгән урын, җөе беленмәслек итеп ямалган урын.

**ШТУ'НДА** *ж. мн.* нет, **ШТУНДИ'ЗМ** *м. мн.* нет — штунда, штундизм (Россиядә XIX йөз урталарында барлыкка килгән һәм кулаклар интересын чагылдырган дини мәзһәп).

**ШТУНДИ'СТ** *м.*, **ШТУНДИ'СТКА** *ж.*— штундист, штундизм тарафдары.

**ШТУРВА'Л** *м.*— штурвал (суднода, самолётта, автомобильдә руль тәгәрмәче).

**ШТУРВА'ЛЬНЫЙ** I — штурвал ...-ы; *штурвальное колесо* — штурвал тәгәрмәче.

**ШТУРВА'ЛЬНЫЙ** II *м. в знач. сущ.*— штурвалчы, штурвалда торучы.

**ШТУРМ** *м.*— штурм, штурмлау; *идти на штурм* — штурмга бару; *штурм твердынь капитализма* — капитализм нигезләрен штурмлау.

**ШТУ'РМАН** *м.*— штурман (1. зур судноларда һәм хәрби судноларда корабль йөртүче; 2. кечкенә пароходларда капитан ярдәмчесе; 3. авиациядә самолётларны йөртү белгече).

**ШТУ'РМАНСКИЙ** — штурман ...-ы, штурманнар ...-ы; *штурманское училище* — штурманнар мәктәбе.

**ШТУ'РМАНСТВО** *ср. мн.* нет — штурманлык, штурманлык дәрәҗәсе, штурманлык хезмәте; *получить штурманство* — штурманлык дәрәҗәсе алу.

**ШТУРМОВА'ТЬ** *несов.*— штурмлау, штурм ясау; *штурмовать крепость* —крепостьны штурмлау; *альпинисты штурму-*

*ют вершины* — альпинистлар тау түбәләренә штурм ясыйлар.

**ШТУРМОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— штурмлану, штурм ясалу.

**ШТУРМОВИ'К** *м.*— штурмовик (1. артык биек булмаган югарылыктан җирдәге объектларга һөҗүм итүче хәрби самолёт; 2. шушы самолётның очучысы).

**ШТУРМОВО'Й** — штурм ...-ы, штурм ясау ...-ы; штурм вакытында файдаланыла торган; *штурмовые лестницы* — штурм баскычлары (штурм вакытында крепостька үтеп керү өчен аның стеналарына эленеп куела торган баскычлар); *штурмовая авиация* — штурм авиациясе.

**ШТУРМОВЩИ'НА** *ж. мн.* нет, *неодобр.*— штурмовщина, штурмчылык, штурмлап эшләү (эшне начар оештыру нәтиҗәсендә, башта планны үтәмичә, соңга таба, мәсәлән, ай азагында, ашык-пошык эшләү).

**ШТУРТРА'П** *м. мор.*— штуртрап (судно койрыгында баудан ишелгән баскыч).

**ШТУРТРО'С** *м. мор.*— штуртрос (штурвалдан рульгә тоташтырылган чылбыр яки трос).

**ШТУФ** *м. геол.*— штуф (минерал кисәге, руда кисәге).

**ШТУ'ЦЕР** *м.*— штуцер (1. борынгы хәрби мылтык; 2. сырлы көпшәле аучы мылтыгы).

**ШТУ'ЧКА** *ж. разг. фам.*— к. штука 2, 3, 4, 5, 6.

**ШТУ'ЧНИК** *м.*, **ШТУ'ЧНИЦА** *ж. спец.*— эш башыннан эшләүче, эш башыннан акча алучы (күбрәк тегүчеләр турында).

**ШТУ'ЧНЫЙ** — 1. берәмләп..., данәләп..., берәмләп сатыла торган, данәләп сатыла торган; *штучная продажа* — берәмләп сату; *штучный товар* — берәмләп сатыла торган товар; 2. *спец.* эш башыннан..., эш башыннан... торган; *штучная работа* — эш башыннан эшләү; *штучное вознаграждение* — эш башыннан түләү; 3. *спец. устар.* кисәкләрдән торган, кисәкләрдән җыелган; *штучный пол* — кисәкләрдән җыелган идән (паркет идән).

**ШТЫБ** *м. горн. тех.*—штыб (вак яки вакланган ташкүмер).

**ШТЫК** *м.*— 1. штык; *гранёный штык*— кырлы штык; 2. *перен. воен.* укчы, укчы солдат; *отряд в тысячу штыков* — мең укчы солдаттан торган отряд; 3. *перен. только мн.* гаскәр, гаскәрләр; 4. *тех.* к. свинка 3; 5. *мор.* штык (калын бау төене); 6. *спец.* бер көрәк тирәнлегендәге җир катламы.◇ **В штыки** (встретить, принять) *перен.*—нәфрәт белән (каршы алу, кабул итү), дошманлык белән (каршы алу, кабул итү).

**ШТЫКОВА'ТЬ** *несов. с.-х.*— (җирне бер көрәк тирәнлегендә) казу.

**ШТЫКОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. с.-х.*— (бер көрәк тирәнлегендә) казылу.

**ШТЫКОВО'Й** — 1. штык...-ы; *штыковое острие* — штык очы; 2. штык...-ы; штык белән чәнчеп ясалган; *штыковая рана* — штык ярасы; 3. штык ...-ы, штыклар белән..., штыкка штык килеп...; *штыковой бой* — штык сугышы; *штыковая атака* — штыклар белән атака.

**ШТЫК-Ю'НКЕР** *м. воен. истор.*— штык-юнкер (XVIII йөздә артиллериядәге офицер чины, җәяүле гаскәрдә прапорщикка туры килә).

**ШТЫРЕВО'Й** *спец.*— штырь ...-ы, штырьга беркетелгән, штырь белән беркетелгән.

**ШТЫРЬ** *м. спец.*— штырь (1. оя эчендә әйләнә торган күчәр, тимер очы; 2. кире чыкмасын өчен очы сырлы итеп эшләнгән кадак).

**ШУ'БА** *ж.*— 1. тун; *лисья шуба* — төлке тун; 2. *обл.* йон (хайваннарда).◇ **Не шубу шить** *перен. разг. шутл.*— бернәрсәгә дә кирәкми, берингә дә хаҗәте юк, пычагыма да кирәге юк. **Шубы не сошьёшь** *перен. разг. шутл.*— бернәрсәгә дә ярамас, берни эшләп булмас, бернинди файдасы да булмас.

**ШУБЕ'ЙКА** *ж.*— 1. кыска тун (җиңел һәм кыска хатын-кыз туны); 2. *разг. пренебр.* тун кисәге, начар тун; кыска тун.

**ШУБЕНКА** *ж. разг. пренебр.*— к. шубейка 2.

**ШУ'БНИК** *м.*— тун тегүче.

**ШУБНИ'НА** *ж. мн.* нет, *собир. спец.*— иләнгән тиреләр (мех әйберләр тегү өчен).

**ШУ'БНЫЙ** — 1. тун ...-ы; *шубный верх*— тун тышлыгы; 2. тун тегү ...-ы; *шубный цех*— тун тегү цехы.◇ **Шубный клей** — агач җилеме.

**ШУГА'** *ж.*— сиң, зим (көз көне яки язын елга өстен тутырып ага торган вак көпшәк боз).

**ШУГА'Й** *м. обл. старин.*—шугай (1. кыска кофта; 2. карчыклар сарафаны).

**ШУГА'ТЬ** *несов. простореч. фам.*— куркыту, кычкыру, куркытып куу.

**ШУГНУ'ТЬ** *однокр. простореч. фам.*— куркыту, куркытып куып җибәрү.

**ШУ'ЙЦА** *ж. книж. старин.*— сул кул.

**ШУ'ЛЕР** *м.*— 1. шулер, хәйләләп уйнаучы (карта уенында); 2. *разг. бран.* шулер, алдакчы, хыянәтче, мошенник.

**ШУ'ЛЕРСКИЙ** — 1. шулер ...-ы, шулерлар ...-ы, шулерга хас; *шулерская игра* — шулерлар уены.

**ШУ'ЛЕРСТВО** *ср. мн.* нет — шулерлык, хәйләләп уйнау.

**ШУ'ЛЕРША** *ж.*— к. шулер.

**ШУМ** *м.*— 1. тавыш, шау, шау-шу, шаулау; *поднять шум* — тавыш куптару; *шум леса* — урман шаулавы; 2. *перен. разг. только ед.* тавыш, шау-шу, кычкырыш; *что за шум, а драки нет?*— бу нинди кычкырыш, ә сугышу юк? 3. *перен. только ед.* шау-шу, ыгы-зыгы; *в городах утих вседневный шум* (Пушкин) — шәһәрләрдә көн дә була торган ыгы-зыгы тынып калды; *жизнь прошла скоро и без шума* — тормыш тиз һәм шау-шусыз үтте; 4. *перен., только ед.* шау-шу, тавыш; *книга вызвала много шума* — китап бик зур шаушу кузгатты.◇ **Шум в голове** — к. шуметь. **Шум в ушах** — к. шуметь.

**ШУМЁР** *м. театр.*— шумёр (театрда тавыш эффекты ясау эшләре белән җитәкчелек итүче).

**ШУМЕ'ТЬ** *несов.*— 1. шаулау; *шумит море* — диңгез шаулый; *шумит высокий клён* — биек өрәңге шаулый; 2. тавышлану, тавыш куптару, шаулау, шау-шу күтәрү, кычкырышу; *всюду люди—шумят, суетятся* (Некрасов) — бөтен җирдә кешеләр — тавышлананалар, ыгы-зыгы киләләр; 3. *разг.* шаулау, шау-шу кузгату; *авторитет, давно шумевший ложно, вы разрушаете* (Некрасов) — күптәннән ялган рәвештә шау-шу кузгаткан авторитетны сез җимерәсез; *имя писателя шумит на весь мир* — язучының исеме бөтен дөньяга шаулый. ◇ **Шумит в голове** — баш шаулый (тирән кичерешләрдән, аракы эчкәннән соң). **Шумит в ушах** — колак шаулый.

**ШУМИ'ХА** *ж. разг.*— к. шум 4.

**ШУМЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — тавышлылык, тавыш куптаручанлык, тавышланучанлык, шаулаучанлык, шау-шулылык, шау-шу күтәрүчәнлек.

**ШУМЛИ'ВЫЙ** — тавышлы, тавышланучы, тавышланучан; шау-шулы, шаулы, шаулаучы, шаулаучан; *шумливые дети*—тавыш куптаручан балалар.

**ШУ'МНО** *нареч.*— 1. тавышланып, шаулашып, шаулап, шау-шу белән; *дети шли, шумно разговаривая между собой* — балалар тавышланып сөйләшә-сөйләшә баралар иде; 2. шау-шу эчендә, шау-шу белән, ыгы-зыгы эчендә; *день прошёл шумно* — көн шау-шу эчендә узды.

**ШУ'МНЫЙ** — 1. тавышлы, шау-шулы, шаулый торган, шау-шу күтәрә торган; *шумная компания* — шау-шулы компания; 2. шау-шулы, шау-шу белән тулган, ыгызыгылы, ыгы-зыгы белән тулган; *шумный день* — шау-шулы көн; *шумная жизнь* — ызгы-зыгылы тормыш; 3. шау-шулы, шаушу куптара торган, шау-шу куптарган, дөнья шаулатучы, дөнья шаулаткан; *шумный успех* —шау-шу куптарган уңыш; 4. *лингв. только полн. формы* — тавышлы; *шумные согласные* — тавышлы тартыклар (мәсәлән, п, т, ш һ. б.).

**ШУМОВИ'К** *м.*— 1. тавыштан куркып каршыга чыккан җәнлек, тавыштан куркып чыккан җенлек; 2. шумовик (а. *театр.* тавышчы, тавыш эффекты ясаучы; б. *муз.* тавышлы музыка коралларында уйнаучы музыкант).

**ШУМО'ВКА** *ж.*— сөзгеч, тишекле чүмеч.

**ШУМОВО'Й** — 1. *муз., театр.* тавышлы; *шумовой оркестр* — тавышлы оркестр (кашык, шешә, пычак һ. б. кагып уйный торган оркестр); 2. *муз., театр.* тавыш ...-ы; *шумовые эффекты* — тавыш эффектлары; 3. *охот.* тавыштан куркып каршыга чыккан, тавыштан куркып чыккан; *шумовой заяц* — тавыштан куркып чыккан куян.

**ШУМО'К** *м. разг. фам.*— әкрен тавыш, ишетелер-ишетелмәс тавыш. ◇ **Под шумок** *разг.*— шыпырт кына, астыртын, кеше күрмәгәндә.

**ШУ'РИН** *м.*— каенага, каене.

**ШУРОВА'ТЬ** *несов. тех.*— (яна торган мичкә) утын ташлап болгату, (яна торган мичкә) ягулык ташлап болгату.

**ШУРУ'М-БУРУ'М** *м. мн.* нет — 1. *разг. фам.* шорым-борым, иске-москы; 2. *простореч.* шорым-борым, астыртын эшләр.

**ШУРУ'П** *м.*— шөреп, винт.

**ШУРФ** *м. горн.*— шурф (казылма байлыклар эзләү өчен ясалган коесыман корылма).

**ШУРФОВА'ТЬ** *несов. горн.*— шурф казып эзләү, шурф казып тикшерү (казылма байлыкларны).

**ШУРША'ТЬ** *несов.*—кыштырдау, шытырдау; *шуршат камыши* — камышлар кыштырдыйлар; *шуршит песок под ногами* — аяк астында ком шытырдый.

**ШУ'РЫ-МУ'РЫ** *только мн. нескл. разг. фам.*— гыйшык бәйләнешләре, мәхәббәт бәйләнешләре.

**ШУРЬЯ'К** *м. обл.*— к. шурин.

**ШУСТ** *м. спец.*— шуст (ату кораллары-ның көпшә каналларын чистарту, турайту җайланмасы).

**ШУСТОВА'ТЬ** *несов. спец.*— шуст белән чистартып турайту.

**ШУ'СТРЫЙ** *разг.*— җитез, өлгер, тере, үткен, шук; *шустрый мальчишка* — җитез малай.

**ШУТ** *м.*— 1. шамакай (электә патша сарайларында, бояр йортларында байларны, кунакларны көлдерү өчен тотылган кеше); *придворный шут* — сарай шамакае; 2. шамакай, паяц (балаган клоуны); *костюм шута* — шамакай костюмы; 3. *перен. пренебр.* мәзәкче, көлдерүче, сәвәләй; 4. *разг. фам.* шайтан; *шут его знает, что он за человек* (А. Островский)— шайтан белсен, нинди кеше ул.

**ШУТИ'ТЬ** *несов.*— 1. шаяру; *любит шутить* — шаярырга ярата; *шутить с детьми* — балалар белән шаяру; 2. шаярту; *не верьте ему, он шутит* — ышанмагыз аңа, ул шаярта; *я шучу, так на самом деле не было* — мин шаяртам, чынлыкта исә алай булмады; 3. уйламый эшләү, шаяру; *с ним не шути: он сильнее тебя* — аның белән шаярма: ул синнән көчлерәк; 4. көлү, мыскыллап көлү, мыскыл итү. ◇ **Чем чорт не шутит!** *разг.*— кем белсен, әллә нәрсә килеп чыгуы ихтимал! **Шутить с огнём** *перен.*—ут белән шаяру, ут белән уйнау (начар, аяныч нәтиҗәләр килеп чыгу турында). **Шутки (шутку) шутить** — 1. шаяру, уйнау, уен уйнау; *ты думаешь, Любим Торцов пришёл шутки шутить?* (А. Островский)— Любим Торцов уен уйнарга килгән дип уйлыйсыңмы әллә? 2. көлү, мыскыллау, мыскыл итү.

**ШУТИ'ХА** *ж.*— 1. к. шут 1, 2, 3; 2. *устар.* шутиха (фейерверкның бер төре).

**ШУ'ТКА** *ж.*— 1. шаярту, мәзәк, мәзәк итеп әйтелгән сүз, көлкеле сүз; *злая шутка* — зәһәр шаярту; *не обижайся на шутку* — шаяртуга ачуланма; *он не понимает шуток* — ул мәзәк итеп әйтелгән сүзләрне

аңламый; 2. *лит., театр.* көлкеле пьеса; *шутка в одном действии* — бер пәрдәлек көлкеле пьеса. ◇ **Без шуток, кроме шуток** — чыннан да, шаярып әйтмим; *без шуток, я уеду отсюда* — шаярып әйтмим, китәм мин моннан. **Не на шутку** — чынчынлап, чынлап, бик нык; *солнце не на шутку начало уже припекать* (Григорович) — кояш инде чын-чынлап кыздырырга кереште. **Не шутка** — уен түгел, уен эш түгел; *две тысячи пятьсот рублей не шутка!* (Гончаров) — ике мең дә биш йөз сум уен түгел! **Шутка ли** *разг.* — уен эшмени; *шутка ли: переменил закон!* (Грибоедов) — уен эшмени: закон үзгәрткән! **Шутка (ли) сказать** — к. шутка ли. **Шутки в сторону, шутки прочь** — шаяруларны калдырып тор, шаяртуларны куеп тор. **Шутки плохи** — к. плохой. **Шутки шутить** — к. шутить.

**ШУТЛИ'ВО** *нареч.* — шаярып, шаяртып, мәзәк өчен; *шутливо сказать что-нибудь* — шаяртып берәр нәрсә әйтү.

**ШУТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. шаяртырга яратучанлык, шаярырга яратучанлык, жорлык, мәзәкчәнлек; 2. күңеллелек, көлкелелек (шаяру, шаярту характерында булу).

**ШУТЛИ'ВЫЙ** — 1. шаярырга яратучы, шаяртырга яратучы, шаярырга яратучан, шаяртырга яратучан, мәзәкчән; *шутливый человек* — шаяртырга яратучан кеше; 2. күңелле, шаян, көлкеле; *шутливый разговор* — күңелле сөйләшү.

**ШУТНИ'К** *м.*, **ШУТНИ'ЦА** *ж.* — шаярырга яратучы кеше, шаяртырга яратучы кеше, жор кеше, шаян кеше, мәзәкче, көлдерергә яратучы кеше.

**ШУТОВСКО'Й** — шамакай (лар)...-ы, шамакайларга хас; паяц(лар)...-ы, паяцларга хас, сәвәләй(ләр)...-ы, сәвәләйләргә хас; *шутовской колпак* — шамакайлар калфагы; *шутовские выходки* — шамакайларга хас кыланышлар.

**ШУТОВСТВО'** *ср. мн.* нет — шамакайлык, сәвәләйлек; шамакайлар кыланышы, сәвәләйләр кыланышы.

**ШУ'ТОЧНЫЙ** — күңелле, көлкеле, кызыклы, көлдерә торган; *шуточная беседа* — көлкеле әңгәмә. ◇ **Дело не шуточное** — уен эш түгел, эш бик мөһим, эш бик җитди.

**ШУТЯ'** — 1. шаярып, шаяртып; 2. *нареч.* бик җиңел, җиңел генә, шаярып кына, шаярып; *это можно шутя сделать* — моны бик җиңел эшләп була. ◇ **Не шутя** — бик каты, бик нык, чын-чынлап; *он не шутя рассердился* — ул чын-чынлап ачуланды.

**ШУЦЛИ'НИЯ** *ж. спец.* — шуцлиния (урамда хәрәкәт юнәлешен күрсәтүче сызык).

**ШУШУ'КАТЬ** *несов.* — 1. шаулау, кыштырдау, шыбырдау; *тростник шушукал кругом* — әйләнә-тирәдә камышлар шаулый иде; 2. к. шушукаться.

**ШУШУ'КАТЬСЯ** *несов. разг. фам.* — пышпыш сөйләшү, чыш-пыш килеп сөйләшү; гайбәт сату.

**ШУШУ'Н** *м. обл. старин.* — шушун (хатын-кызларда кыска яки озын өс киеме, мәсәлән, кофта, сарафан, күлмәк һ. б.).

**ШХЕ'РЫ** *ед.* нет — шхерлар (диңгез яры буенда су астындагы яки өстендәге кыялар).

**ШХУ'НА** *ж. мор.* — шхуна (ике яки өч мачталы җилкәнле судно).

**Ш-Ш** *междом.* — тш-ш, тавышланма (гыз)! шаулама(гыз)!

# Щ

**ЩАВЕ'ЛЕВЫЙ** — кузгалак ...-ы; *щавелевые щи* — кузгалак ашы; *щавелевая кислота (хим.)* — кузгалак кислотасы (техниканың төрле өлкәләрендә кулланыла торган ак төстәге әче кристаллик матдә).

**ЩАВЕ'ЛЬ** *м. мн.* нет — кузгалак. ◇ **Щавель конский** — ат кузгалагы. **Щавель малый** — чыпчык кузгалагы.

**ЩАВЕ'ЛЬНИК** *м. мн.* нет — 1. к. щавель; 2. *обл.* кузгалак шулпасы (ашы).

**ЩАДИ'ТЬ** *несов.* — 1. аяу, яхшылык (мәрхәмәт, шәфкать) күрсәтү; *не щадить врагов* — дошманнарны аямау, дошманнарга аяусыз булу; 2. саклау, кызгану, аяу; *щадить здоровье* — сәламәтлекне саклау.

**ЩАЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *книж. редко* — к. щадить.

**ЩЕБЕНИ'ТЬ** *несов. спец.* — вакланган таш (кирпеч) җәю; *щебенить мостовую* — юлга вакланган таш (кирпеч) җәю.

**ЩЕБЕНИ'ТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — вакланган таш (кирпеч) җәелү.

**ЩЕБЁНКА** *ж. мн.* нет — к. щебень.

**ЩЕБЁНОЧНЫЙ** — вакланган таш (кирпеч) җәелгән, вакланган таш (кирпеч) түшәлгән; *щебёночное основание мостовой* — юлның вак таш җәелгән нигезе.

**ЩЕ'БЕНЬ** *м. мн.* нет — вак таш, вакланган таш, вакланган кирпеч.

**ЩЕ'БЕТ** *м. мн.* нет, **ЩЕБЕТА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. щебетать.

**ЩЕБЕТА'ТЬ** *несов.* — 1. чәрелдәү, черелдәү, черкелдәү, сайрау, чыр-чыр килү, чыр-чыр итү (карлыгач, кошчык һ. б. шундый кошлар турында); 2. *перен. разг.* бертуктаусыз сөйләп тору, чәкердәү (гадәттә хатын-кызлар, балалар турында).

**ЩЕБЕТЛИ'ВЫЙ** *обл.* — 1. чәрелдәүчән, черелдәүчән, черкелдәүчән; *щебетливая*

*пташка* — черелдәүчән кошчык; 2. *перен.* такылдык, күп сөйләүчән, тел бистәсе.

**ЩЕБЕТУ'НЬЯ** *ж. разг.* — чәрелдек, черелдек, черкелдек; *ласточка-щебетунья* — черелдек-карлыгач.

**ЩЕБЕШО'К** *м. простореч.* — вак таш кисәге, вакланган таш, кирпеч кисәге.

**ЩЕБРЕ'Ц** *м. бот.* — к. чебрец.

**ЩЕГЛЁНОК** *м.* — 1. купшыл баласы; 2. к. щегол.

**ЩЕГЛО'ВКА** *ж.* — ана купшыл.

**ЩЕГЛЯ'ТНИК** *м.* — купшыл ауларга яратучы.

**ЩЕГЛЯ'ЧИЙ** — купшыл ...-ы; *щеглячье гнездо* — купшыл оясы.

**ЩЕГО'Л** *м.* — купшыл, купшы чыпчык (кош).

**ЩЕГОЛЕВА'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — купшылык, көязлек, купшы кыяфәт.

**ЩЕГОЛЕВА'ТЫЙ** — 1. купшы (киенгән), көяз (киенгән), купшыларча киенгән; *щеголеватый молодой человек* — купшы (киенгән) егет; 2. купшы итеп тегелгән, купшыларча тегелгән; *щеголеватый костюм* — купшы итеп тегелгән костюм.

**ЩЕГОЛИ'ХА** *ж.*, **ЩЕГОЛИ'ЦА** *ж. обл.* — купшы киенгән хатын-кыз, көяз хатын-кыз, купшы киенергә яратучы хатын-кыз.

**ЩЁГОЛЬ** *м.* — купшы киенгән кеше, көяз кеше, купшы киенергә яратучы кеше.

**ЩЕГОЛЬНУ'ТЬ** *однокр.* — 1. купшыланып, көязләнеп алу; 2. купшыланып, көязләнеп йөреп алу; 3. мактанып алу.

**ЩЕГОЛЬСКО'Й** — купшы, бик купшы, бик көяз; *щегольской вид* — купшы кыяфәт.

**ЩЕГОЛЬСТВО'** *ср. мн.* нет — купшылык, көязлек, купшыланырга (көязләнергә) ярату; франтларча киенергә ярату; *отличаться щегольством* — үзенең купшылыгы белән аерылып тору.

**ЩЕГОЛЯ'ТЬ** *несов.* — 1. купшылану, көязләнү, купшы (көяз) киенү; *любит щеголять* — купшы киенергә ярата; 2. *разг.* купшыланып, көязләнеп йөрү; *щеголять в новом платье* — яңа күлмәк киеп, купшыланып йөрү; 3. *перен.* мактану, үз-үзен күрсәтергә тырышу; *щеголяет знаниями* — белеме белән мактана; 4. *простореч.* вакыт уздыру, вакыт уздырып йөрү, йөрү; *с купеческими сынками щеголял* — сәүдәгәр малайлары белән вакыт уздырып йөрде.

**ЩЕДРИ'ВЫЙ** *обл.* — шадра; *щедривое лицо* — шадра бит.

**ЩЕДРИ'НА** *ж. обл.* — шадра бөртеге.

**ЩЕ'ДРИТЬСЯ** *несов. обл.* — юмарт булу, юмартлану.

**ЩЕ'ДРО** *нареч.* — мул, күп, мул итеп, күп итеп.

**ЩЕДРОВА'ТЫЙ**, **ЩЕДРОВИ'ТЫЙ** *обл.* — к. щедривый.

**ЩЕ'ДРОСТЬ** *ж. мн.* нет — юмартлык.

**ЩЕДРО'ТЫ** *ед.* нет, *книж.* — мәрхәмәтлекләр, игелекләр, рәхимлекләр, мул итеп бирелгән бүләкләр. ◇ **От (своих) щедрот** подарить, дать) *книж. устар.*, *теперь ирон.* — үз кесәңнән, үзеңнән (бирү, бүләк итү).

**ЩЕ'ДРЫЙ** — 1. юмарт; *щедрый человек* — юмарт кеше; *щедрый на обещания* — вәгъдәләр бирергә юмарт; 2. кыйммәтле; бәһалы, мул; *щедрые подарки* — кыйммәтле бүләкләр. ◇ **Щедрою рукою** — юмарт кулдан, саранланмыйча, үзенекен кызганмыйча; *щедрою рукою раздавал подарки* — юмарт кулдан бүләкләр өләшә торган иде.

**ЩЕДУ'ШНЫЙ** *устар.* — к. тщедушный.

**ЩЕКА'** *ж.* — 1. яңак; *ударить по щеке* — яңакка сугу; *щека револьвера* — револьвер яңагы; 2. *спец.* к. губа I во 2 знач. ◇ **За обе щеки (есть, уписывать)** *разг.* — авыз тутырып ашау, йотлыгып ашау, комагайланып ашау.

**ЩЕКА'СТЫЙ** *простореч.* — тулы яңаклы; *щекастый ребёнок* — тулы яңаклы бала.

**ЩЕКО'ЛДА** *ж.* — тимер бик, келә, бикләвеч (капкада, тышкы ишектә); *заложить дверь на щеколду* — ишекнең келәсен төшерү.

**ЩЁКОТ** *м. мн.* нет, *спец.* — к. щекотать II.

**ЩЕКОТА'ТЬ** I *несов.* — 1. кытыклау; *щекотать детей вредно* — балаларны кытыклау зарарлы; 2. *безл.* кытык килү, кычыту, кымырҗу, кымырҗып тору (тамакта, борын эчендә, колакта); *у меня в горле щекочет* — тамагым кымырҗып тора; 3. *перен.* кытыклау, кәефләндерү, дәртләндерү; *щекотать нервы* — нервларны кытыклау.

**ЩЕКОТА'ТЬ** II *несов. спец.* — чутылдау, сайрау (сандугач), шыгырдау (саескан).

**ЩЕКОТИ'ТЬ** *несов. обл.* — к. щекотать I.

**ЩЕКО'ТКА** *ж. мн.* нет, *разг.* — 1. к. щекотать I; 2. кытык, кытыклану; *бояться щекотки* — кытыкланудан курку.

**ЩЕКОТЛИ'ВОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. четреклелек, кыенлык; 2. кытыкланучанлык.

**ЩЕКОТЛИ'ВЫЙ** — 1. кытыкланучан, кытыгы килүчән; *щекотливый человек* — кытыкланучан кеше; 2. *перен.* вакчыл, чокчынучан; *он очень щекотлив в денежных делах* — акча мәсьәләсендә ул бик чокчынучан кеше; 3. четрекле, кыен, авыр; *щекотливый вопрос* — четрекле мәсьәлә, кыен мәсьәлә.

**ЩЕКО'ТНО** *в знач. сказ.* — кытыгы (м,н) килә; *не трогай меня, мне щекотно* — мина тимә, минем кытыгым килә.

**ЩЕЛЕВА'ТЫЙ** — ярык, ярыклы; *щелеватая доска* — ярык такта.

**ЩЕЛЕВО'Й** — к. щелеватый.

**ЩЕЛИ'НА** *ж.* — зур ярык.

**ЩЕЛИ'ННЫЙ** *лингв.* — к. фрикативный.

**ЩЕЛИ'СТЫЙ** *обл.* — күп ярыклы; *щелистый пол* — күп ярыклы идән.

**ЩЁЛК** I *обл.* — к. щелчок.

**ЩЁЛК** II *м. разг.* — 1. шартлау; шакылдау, шалтырау, шылтырау; *послышался щёлк ключа* — ачкыч шалтыравы ишетелде; 2. чутылдау; сайрау; 3. яру (чикләвек, көнбагыш кебекләрне); 4. *в знач. сказ.* чиртте(м, н); *она щёлк его по носу* — ул аның борынына чиртте.

**ЩЁЛКА** и **ЩЕ'ЛКА** *ж.*— кечкенә ярык, тар ярык, ярык; *смотреть в щёлку* — кечкенә ярыктан карау.

**ЩЁЛКАТЬ** *несов.*— 1. чиртү; *щёлкать по лбу* — маңгайга чиртү; 2. шартлату; *щёлкать пальцами* — бармак шартлату; *извозчик щёлкает кнутом* — извозчик чыбыркы шартлата; 3. шакылдату, шыкырдату; *щёлкают зубами* — тешләрен шакырдаталар; 4. шалтырау, шылтырау; *щёлкает замок* — йозак шылтырый; 5. чутылдау, сайрау (кайбер кошлар турында); *в саду щёлкал соловей* — бакчада сандугач чутылдый иде; 6. яру (чикләвек, көнбагыш кебекләрне).

**ЩЕЛКА'ТЬ** *несов. разг.*— к. щёлкать 6.

**ЩЁЛКАТЬСЯ** *несов. страд.*— ярылу (көнбагыш, чикләвек кебекләр).

**ЩЕЛКА'ТЬСЯ** *несов. разг. страд.*— к. щёлкаться.

**ЩЁЛКНУТЬ** *однокр.*— 1. чиртеп җибәрү, чиртеп алу; *щёлкнул по носу* — борынына чиртеп җибәрде; 2. шартлатып алу, шартлатып җибәрү; *щёлкнул пальцами* — бармак шартлатып алды; 3. шакылдатып (шыкырдатып) алу, шыкырдатып кую; *щёлкнул зубами* — тешләрен шыкырдатып алды; 4. шалтыратып (шылтыратып) алу, шалтыратып (шылтыратып) кую, шалтыратып (шылтыратып) җибәрү; *щёлкнул шпорами*—шпорларын шалтыратып куйды; 5. чутылдап алу, чутылдап кую, сайрап җибәрү (кайбер кошлар турында); *в саду щёлкнул соловей* — бакчада сандугач чутылдап куйды.

**ЩЕЛКНУ'ТЬ** *простореч.*— к. щёлкнуть.

**ЩЕЛКОПЁР** *устар. пренебр.*— кәгазь пычратучы, язучы кисәге, талантсыз язучы.

**ЩЕЛКОТНЯ'** *ж. мн.* нет, *разг.*— к. щёлкать.

**ЩЕЛКУ'Н** *м. разг. фам.*— 1. чиртүче; 2. шартлатучы; 3. шалтыратучы, шылтыратучы; 4. чутылдаучы, сайраучы; 5. яручы (чикләвек, көнбагыш кебекләрне); 6. *зоол.* шыртлавык, чыртлака (корткыч коңгыз).

**ЩЕЛКУ'НЬЯ** *ж. разг. фам.*— к. щелкун 1, 2, 3, 4, 5.

**ЩЕЛКУ'ШКА** *ж. разг.*— 1. к. щелчок 1; 2. *(детская игрушка)* чыртлавыч; 3. *обл.* чикләвек яргыч.

**ЩЁЛОК** *ж. мн.* нет — селте эретмәсе, селтеле су, көл селтесе.

**ЩЕЛОЧИ'ТЬ** *несов.*— селтеләү.

**ЩЕЛОЧИ'ТЬСЯ** *несов. страд.*—селтеләнү.

**ЩЕЛОЧНО'Й** — 1. селтеле; *щелочная вода* — селтеле су; 2. селте ...-ы; *щелочная реакция* — селте реакциясе.

**ЩЁЛОЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *хим.*— селтелелек, селтелелек дәрәҗәсе.

**ЩЁЛОЧЬ** *м. хим.*— селте.

**ЩЕЛЧО'К** *м.*— 1. чиртү; *щелчок по носу* — борынга чиртү; 2. *перен. (неприятность, оскорбление)* күңелсезлек, мәсхәрә, мыскыл ителү.

**ЩЕЛЬ** *ж.*— ярык; *смотреть в дверную щель* — ишек ярыгыннан карау. ◇ **Голосовая щель** *анат.*— тавыш ярыгы, тавыш юллыгы.

**ЩЕЛЯ'СТЫЙ** *обл.*— к. щелистый.

**ЩЕМИ'ТЬ** *несов.*— 1. *(сжимать, стискивать)* кысу; 2. *перен.* әрнетү, сыкрату, үзәкне өзү; *щемящая душу песня* — үзәкне өзә торган җыр; 3. *перен. безл.* кысу, чәнчешү, сызлау, чәнчү, әрнү; *у меня щемит грудь* — минем күкрәгем кыса; *мне щемит сердце* — минем йөрәгем чәнчи (чәнчешә), йөрәгем әрни.

**ЩЕНИ'ТЬСЯ** *несов.*— балалау (эт, бүре, төлке һ. б. турында).

**ЩЁННАЯ** — буаз (эт, бүре, төлке һ. б. турында).

**ЩЕНО'К** *м.*— 1. көчек, эт баласы; 2. *простореч. бран.* маңка малай, маңка; *ведь он перед ним ещё только мальчишка и щенок* — ул аның каршында маңка малай гына бит әле.

**ЩЕНЯ'ЧИЙ** — көчек ...-ы, эт баласы ...-ы; *щенячий писк* — көчек чинавы.

**ЩЕПА'** *ж.*— 1. *собир.* йомычка; 2. агачтан кырып ясалган әйбер (мәсәлән, агач таяк).

**ЩЕПА'ЛЬНЫЙ** — агач юну ...-ы, агач кыру ...-ы; *щепальные приспособления* — агач юну җиһазлары.

**ЩЕ'ПАНЫЙ** — ярып алынган, телеп алынган; *щепаная лучина* — телеп алынган чыра.

**ЩЕПА'ТЬ** *несов.*— яру, телү; *щепать лучину* — чыра телү; *щепать дранку* — дранча яру.

**ЩЕПА'ТЬСЯ** *несов. страд.*— ярылу, теленү.

**ЩЕПЕ'ННИК** *м. обл. устар.*— 1. агачтан кырып әйберләр ясау остасы; 2. агач товарлар белән сәүдә итүче.

**ЩЕПЕТИ'ЛЬНИК** *м. устар.*— агач товарларны йөртеп сатучы кеше.

**ЩЕПЕТИ'ЛЬНЫЙ** — 1. *устар.* галантерея ...-ы, парфюмерия...-ы; *щепетильные товары* — галантерея товарлары; 2. *перен. пренебр. устар.* вакчыл, вак-төякләргә әһәмият бирүче; 3. *перен.* җентекләүчән, чокчынучан, педант, таләпчән; *он очень щепетилен в денежных делах* — акча мәсьәләсендә ул бик җентекләүчән (чокчынучан, таләпчән) кеше.

**ЩЕ'ПКА** *ж.*— йомычка, чыра; *щепки на растопку печей* — мич ягу өчен хәзерләнгән чыралар.

**ЩЕПНО'Й** — агач..., агачтан ясалган; *щепная посуда* — агач савыт; *щепные изделия* — агачтан ясалган әйберләр.

**ЩЕПО'ТКА** *ж.*— к. щепоть.

**ЩЕ'ПОТЬ** *ж.*— (бер) чеметем; *щепоть чаю* — бер чеметем чәй.

**ЩЕПЯНО'Й** — к. щепной.

**ЩЕРБА'ТЫЙ**—1. шадра, шадралы; *щербатое лицо* — шадра бит; 2. кытыршы; *щербатый пол* — кытыршы идән; 3. тешсез (бер теше янсә бернчә теше төшкән кеше).

**ЩЕРБИ'НА** *ж.* — 1. сыр, кителеп төшкән (кителеп беткән) урын; *нож со щер-*

*бинами* — йөзе кителеп беткән пычак; 2. шадра бөртеге (биттә).

**ЩЕРБИ'ТЬ** *несов. обл.* — сырландыру, тешләндерү, кыршалдыру, китекләндерү; *щербить косу о камни* — чалгыны ташка бәреп китекләндерү.

**ЩЕРБИ'ТЬСЯ** *несов. обл.*—сырлану, кыршалу, китекләнү; *коса щербится о камни* — чалгы ташка бәрелеп китекләнә.

**ЩЕ'РИТЬ** *несов.* — 1. ыржайту; *щерить зубы* — тешләрне ыржайту; 2. *обл.* кабарту, тырпайту; *щерить шерсть* — йонын тырпайту.

**ЩЕ'РИТЬСЯ** *несов.* — 1. ыржаю, теш ыржайту; 2. йонын кабарту, йонын тырпайту.

**ЩЕТИ'НА** *ж. мн.* нет — 1. щетина, дуңгыз кылы; *хребтовая щетина* — сырт буе кылы; 2. *разг.* тырпаеп торган (чәч, йон) сакал; тырпаеп торган (калган) үлән, камыл; *они зашагали по щетине скошенного хлеба* — алар урып алынган игеннең тырпаеп калган камылы буйлап китеп бардылар.

**ЩЕТИ'НИСТЫЙ**—каты, тырпаеп тора торган; *щетинистые волосы* — тырпаеп тора торган чәч.

**ЩЕТИ'НИТЬ** *несов. разг.* — йонны кабарту, тырпайту; *кошка щетинит шерсть* — мәче сырт йонын кабарта.

**ЩЕТИ'НИТЬСЯ** *несов.* — 1. кабарыну, сырт йонын (тырпайту) кабарту, сырт йоны кабару (тырпаю); *кошка щетинится* — мәче сырт йонын кабарта; 2. *перен.* ачулану, ачу кабару, кызып китү, кабарыну.

**ЩЕТИ'НКА** *ж.* — щетина кылчыгы, каты чәч бөртеге, кыл бөртеге.

**ЩЕТИ'ННЫЙ** — щетинадан ясалган, кылдан ясалган.

**ЩЕТИНООБРА'ЗНЫЙ** — щетинага охшаган, щетинасыман, кылга охшаган, кылсыман.

**ЩЕТИ'НЩИК** *м.* — 1. *устар.* щетина (кыл) җыючы, щетина (кыл) сатып алып йөрүче кеше; 2. щетинадан (кылдан) төрле әйберләр ясау остасы.

**ЩЁТКА** *ж.* — 1. щётка; *половая щётка* — идән щёткасы; *зубная щётка* — теш щёткасы; 2. *спец. (у лошадей)* бәкәл йоны; 3. щётка (а. *мин.* тыгыз берегеп, өскә таба очлаеп торган кристаллар группасы; *аметистовая щётка* — аметист щёткасы; б. *тех.* динамомашинада әйләнә торган частьлардан хәрәкәтсез частьларга ток үткәреп торучы җайланма).

**ЩЁТКОДЕРЖА'ТЕЛЬ** *м. тех.* — щётка тоткыч, щётка беркеткеч (динамомашинада).

**ЩЁТОЧНИК** *м.* — щётка ясау остасы, щётка ясаучы.

**ЩЁТОЧНЫЙ** — щётка ...-ы; *щёточная колодка* — щётка калыбы; *щёточное производство* — щётка производствосы.

**ЩЁЧНЫЙ** — яңак ...-ы; *щёчные мускулы* — яңак мускуллары.

**ЩИ** *ед.* нет — щи, эшти, кәбестә шулпасы, кәбестә ашы; ...(шулпасы) ашы; *кислые щи* — әчеткән кәбестә шулпасы; *щавелевые щи* — кузгалак шулпасы, кузгалак ашы, ◇ **Кислые щи** *устар.* — әче квас.

**ЩИ'КОЛКА, ЩИ'КОЛОТКА** *ж.* — к. лодыжка.

**ЩИПА'ЛЬНЫЙ** — йолку ...-ы, тетү ...-ы; *щипальный вал* — йолку валы.

**ЩИПА'ТЬ** *несов.* — 1. чеметү; *щипать руку* — кулны чеметү; 2. *перен.* чеметтерү, куыру, яндыру, көйдерү, әчеттерү; *мороз щиплет лицо* — салкын битне чеметтерә; 3. йолыккалау, тарткалау; *он начал щипать ус* — ул мыегын тарткаларга тотынды; 4. (йолкып-йолкып) ашау; *корова щиплет траву* — сыер үлән ашый; 5. язу; *щипать паклю* — чүбек язу; 6. йолку; *щипать гусей* — каз йолку.

**ЩИПА'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *простореч.* к. щипать 1; 2. чеметешү; *перестаньте щипаться* — чеметешүегезне ташлагыз; 3. *страд.* йолкыну.

**ЩИПЕ'Ц** *м. охот.* — эт борыны, эт танавы. ◇ **Крыша щипцом** *архит. обл.* — ике кыеклы түбә.

**ЩИПКО'ВЫЙ** *муз.* — бармаклар белән чиртеп уйнала торган (гитара, арфа, балалайка һ. б. кыллы музыка кораллары турында); *щипковые инструменты* — бармаклар белән уйнала торган кыллы музыка кораллары.

**ЩИПНУ'ТЬ** *однокр.*—1. чеметеп алу; 2. чеметтереп алу, куырып алу, яндырып алу, көйдереп алу, әчеттереп алу; 3. йолкып алу.

**ЩИПО'К** *м.*—1. чеметү; 2. йолку; 3. *разг.* (ике таяктан ясалган) кыстыргыч.

**ЩИПЦО'ВЫЙ** *архит. обл.* — ике кыеклы; *щипцовая крыша* — ике кыеклы түбә.

**ЩИПЦЫ'** *ед.* нет — щипцы, кыскыч, ...ваткыч; *щипцы для орехов* — чикләвек ваткыч; *сахарные щипцы* — шикәр ваткыч.

**ЩИТ** *м.* — 1. калкан; *рыцарь со щитом* — калканлы рыцарь; 2. *перен. ритор. поэт.* — саклаучы, терәк, таяныч; 3. саклавыч, ышыклагыч; *снеговые щиты* — кардан саклавычлар; 4. щит (күргәзмә әйберләре, махсус приборлар һ. б. куела торган такта); *щит с фотографиями* — фотографияләр урнаштырылган щит; *распределительный щит в электротехнике* — электротехникада ток бүлеп таратучы щит; 5. *зоол.* каты кабык. ◇ **На щите (вернуться)** *ритор.* — калканда кайту, җиңелүче булып кайту, җиңелеп кайту. **Поднять (поднимать) на щит** *ритор. перен.* — чамадан тыш мактау, күкләргә күтәрү. **Со щитом (вернуться)** *ритор.* — калкан белән кайту, җиңүче булып кайту, җиңеп кайту.

**ЩЕ'ТИК** *м. зоол.* — агач кандаласы, урман кандаласы.

**ЩИТОВИ'ДНЫЙ** — калкансыман, калканга охшаган; *щитовидная железа* (*анат.*)— калкансыман биз.

**ЩИТОВО'Й** — ышыклагыч...; *щитовые заграждения* — ышыклагыч киртәләр.

**ЩИТО'К** *м.* — 1. калканчык, кечкенә

щит; 2. *зоол.* калканчык; 3. *бот.* чәчәкләр табакчасы, гөл табакчасы.

**ЩИТОНО'СЕЦ** *м.* — 1. *истор.* калканлы сугышчы; калкан йөртүче (урта гасырларда); 2. *зоол.* калканчы (Көньяк Америкада өсте мөгез кабык белән капланган кечкенә хайван).

**ЩИТОНО'СКА** *ж. зоол.* — таш коңгыз, чүгендер коңгызы (корткыч бөҗәк).

**ЩИТООБРА'ЗНЫЙ** — к. щитовидный.

**ЩУ'КА** *ж.* — чуртан.

**ЩУНЯ'ТЬ** *несов. простореч. обл.* — шелтәләү, шелтә белдерү, җиңелчә ачулану (нәрсәгә булса бәйләнеп).

**ЩУП** *м.* — 1. *тех. спец.* щуп, бораү, куыш бораү, кармавыч (җир асты байлыкларын, капчыктагы, тюктагы һ. б. әйберләрне чәнчеп карап тикшергәндә кулланыла торган корал); 2. *обл. спец.* к. вырезка 3.

**ЩУ'ПАЛЬЦЕ** *ср.* — 1. *зоол.* капшавыч; 2. *перен. неодобр.* тырнак, кармак; *щупальца капитализма в колониальных странах* — колониаль илләрдә капитализм тырнаклары.

**ЩУ'ПАТЬ** *несов.* — 1. капшау, капшап карау; *щупать пульс* — пульсны капшап карау; *щупать карманы в поисках спичек* — шырпы эзләп, кесәне капшап карау; 2. *перен.* сынау, сынап карау, җентекләп күзәтү.

**ЩУ'ПИК** *м.* — 1. *спец.* к. щуп; 2. *зоол.* кармавыч (бөҗәкләрдә).

**ЩУ'ПЛЫЙ** — 1. *обл. спец.* йомшак, көпшәк; *щуплое дерево* — көпшәк агач; 2. ач; *щуплое зерно* — ач орлык; 3. *разг.* зәгыйфь, көчсез, йомшак, хәлсез; *щуплый человек* — зәгыйфь кеше.

**ЩУР** I *м.* — бүздәк, корташар (кош).

**ЩУР** II *м. этнол.* — элгәре баба, ыру башлыгы, йорт иясе (славян мифологиясендә).

**ЩУРЁНОК** *м.* — чуртан баласы.

**ЩУ'РИТЬ** *несов.*: **щурить глаза** — күзне кысу.

**ЩУ'РИТЬСЯ** *несов.* — күз кысу; *щуриться от солнца* — кояштан күзне кысу.

**ЩУ'ЧИЙ** — чуртан ...-ы; *щучья икра* — чуртан икрасы. ◇ **По щучьему велению** — чуртан әмере белән (әкиятләрдә).

**ЩУ'ЧИНА** *ж. мн.* нет — чуртан ите.

**ЩУ'ЧКА** *ж. мн.* нет, *бот.* — болытчыл (үлән).

# Э

**Э** *межд.* — э, э, э-э-э (гаҗәпкә калуны, аптырап калуны белдергәндә әйтелә); *э, позвольте, Пётр Иванович, я расскажу.— Э, нет, позвольте уж я...* (Гоголь) — э-э-э, туктагыз, Петр Иванович, мин сөйләп бирим.— Ә-э-э, юк инде, мин үзем ...; *э, что с тобой говорить!* — э, нәрсә синең белән сөйләшеп торырга!

**ЭБЕ'НОВЫЙ**: **эбеновое дерево** — карагач.

**ЭБОНИ'Т** *м. мн.* нет, *спец.* — эбонит (резина кушылмаларыннан ясала торган каты материал).

**ЭБОНИ'ТОВЫЙ** *спец.* — эбонит, эбониттан эшләнгән; *эбонитовая палочка* — эбонит таякчык.

**ЭВАКОПУ'НКТ** *м. спец.* — эвакопункт, эвакуация пункты.

**ЭВАКУА'ТОР** *м.* — эвакуатор, эвакуация эшләрен башкаручы кеше.

**ЭВАКУАЦИО'ННЫЙ** — 1. эвакуация...-ы; эвакуацион; *эвакуационный период* — эвакуация чоры.

**ЭВАКУА'ЦИЯ** *ж.* — эвакуация, эвакуацияләү (халыкны, учреждениеләрне, предприятиеләрне дошман һөҗүм итү куркынычы яки берәр табигый бәла-каза куркынычы булган урыннардан оешкан рәвештә башка урынга күчерү); *эвакуация пленных на родину* — пленга төшкән кешеләрне туган илләренә эвакуацияләү.

**ЭВАКУИ'РОВАННЫЙ** — (куркыныч урыннан, сугыш кырыннан) эвакуацияләнгән, күчеп килгән, күчереп китерелгән; *эвакуированные люди* — эвакуацияләнгән кешеләр.

**ЭВАКУИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — эвакуация ясау, эвакуацияләү, сугыш мәйданыннан тылга күчерү.

**ЭВАКУИ'РОВАТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов.* эвакуацияләнү, тылга күчү, тылга күчеп килү; *госпиталь эвакуировался* — госпиталь эвакуацияләнде; 2. *несов. страд.* эвакуация ясалу, эвакуацияләнү, тылга күчерелү.

**ЭВАПОРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *науч.* — эвапорация, парга (буга) әйләндерү, парга (буга) әйләнү.

**ЭВДЕМОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.* — эвдемонизм (кешенең яшәү максаты шәхси бәхеткә омтылу дип өйрәтүче идеалистик тәгълимат).

**ЭВЕ'НКИ** *мн.* — эвенк халкы, эвенклар (Көнчыгыш Себердә яшәүче халык, революциягә кадәр тунгуслар дип аталганнар).

**ЭВЕНКИ'ЙСКИЙ** — эвенк...-ы; эвенклар...-ы; эвенкларча..., эвенкларга хас; *эвенкийский язык* — эвенк теле.

**ЭВЕ'НСКИЙ** — эвен...-ы; эвеннар...-ы; эвеннарча..., эвеннарга хас; *эвенский язык* — эвен теле.

**ЭВЕНТУА'ЛЬНЫЙ** *книж.* — эвентуаль, билгеле очракта мөмкин булган, билгеле шартларда мөмкин булган; *необходимо*

*предвидеть эвентуальное обострение кризиса* — кризисның билгеле шартларда мөмкин булган кискенләшүен алдан күрә белергә кирәк.

**ЭВЕ'НЫ** *мн.*— эвеннар, эвен халкы (Якутиядә, Охот диңгезе буенда һәм Камчаткада яшәүче халык, революциягә кадәр ламутлар дип аталганнар).

**ЭВКАЛИ'ПТ** *м. бот.*— эвкалипт (агач).

**ЭВКАЛИ'ПТОВЫЙ** *бот.*— эвкалипт...-ы; *эвкалиптовый лист* — эвкалипт яфрагы.

**ЭВОЛЬВЕ'НТА** *ж. мат.* — эвольвента (бирелгән яссы кәкренең билгеле бер кагыйдә буенча эшләнгән җәелмәсе).

**ЭВОЛЮ'ТА** *ж. мат.*— эволюта (җәелмәле яссы кәкре).

**ЭВОЛЮЦИОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — эволюционизм (1. эволюцион үсеш турындагы тәгълимат, җир йөзендәге барлык нәрсә өзлексез үсеп, үзгәреп тора дип өйрәтүче тәгълимат; 2. үсеш процессында революцион үзгәрешләрне, кискен сикерешләрне кире кагучы идеалистик тәгълимат).

**ЭВОЛЮЦИОНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— үсеш кичерү, үсеш процессын (кичерү) кичереп тору, үзгәреш кичерү, үзгәреш процессын (кичерү) кичереп тору; *наука и техника постоянно эволюционируют* — фән һәм техника даими рәвештә үсеш процессын кичерәләр.

**ЭВОЛЮЦИОНИ'СТ** *м. книж.*— эволюционист, эволюционизм тарафдары.

**ЭВОЛЮЦИОНИ'СТСКИЙ, ЭВОЛЮЦИОНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— 1. эволюционистик, эволюционизм...-ы; эволюционист...-ы; эволюционистлар ...-ы; эволюционистларча..., эволюционистларга хас; *эволюционистские взгляды* — эволюционистлар карашы.

**ЭВОЛЮЦИО'ННЫЙ** *книж.*— эволюцион, эволюция...-ы; *эволюционная теория* — эволюцион теория; *эволюционный процесс* — эволюцион процесс, эволюция процессы.

**ЭВОЛЮ'ЦИЯ** *ж.*— 1. *только ед.* эволюция, үсеш, үсеш процессы; үзгәреш, үзгәреш процессы; *эволюция искусства* — сәнгатьнең эволюциясе, үсеш процессы; 2. *только ед. филос.* эволюция, акрынлап өзлексез үсеш, сыйфат үзгәрешләренә алып баручы сан-микъдар үзгәреше; 3. *только мн. воен.* эволюцияләр, манёврлар, стратегик яки тактик хәрби хәрәкәтләр; *морские эволюции* — диңгез эволюцияләре; 4. *только мн. спорт.* гимнастик хәрәкәтләр, спорт хәрәкәтләре.

**Э'ВОН, Э'ВОТ** *нареч. простореч. обл.* — әнә анда, әнә тегендә.

**Э'ВРИКА** *межд.*— эврика! таптым! ура! (берәр нәрсәне чишү, уйлап табу яки башка берәр яхшы фикер килү шатлыгыннан әйтелә торган сүз).

**ЭВРИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *науч.*— эвристика (тикшерү, тикшерену ысуллары системасы яки шушы ысуллар турындагы тәгълимат).

**ЭВРИСТИ'ЧЕСКИЙ** — эвристик, эвристика...-ы; *эвристический метод преподавания* — эвристика методы белән укыту (куелган мәсьәләне укучының үзеннән чиштерүгә юнәлтелгән сораулар методы).

**ЭВФЕМИ'ЗМ** *м. лингв.*— эвфемизм (берәр нәрсә хакында турыдан-туры әйтү уңайсыз, тупас килеп чыгу ихтимал булган очракларда башка сүзләр белән әйтү, мәсәлән, „корсакка узган“ диясе урынга „йөкле“ дип әйтү).

**ЭВФЕМИСТИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.* — эвфемизм...-ы, эвфемистик; *эвфемистические выражения* — эвфемистик сүзләр; *эвфемистические случаи в стиле* — стильдә эвфемизм очраклары.

**ЭВФОНИ'ЧЕСКИЙ** *книж. лит.* — эвфоник, матур яңгырашлы, аһәңле; *эвфонический подбор звуков* — авазларның аһәңле сайланышы.

**ЭВФОНИ'Я** *ж. мн.* нет — 1. *книж.* эвфония, ягымлы яңгыраш, матур аһәң, матур яңгыраш, матур тавыш; 2. *лит.* эвфония (матур әдәбиятта билгеле бер художество эффекты бирә торган авазлар җыелмасы).

**ЭВФОРИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.*— эвфония (берәр авыру яки наркотиклар йогынтысы белән барлыкка килүче ниндидер бер рәхәтлеккә, ләззәтлелеккә чумдыра торган хәстәлек күренеше).

**ЭВФУИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *лит.*— эвфуизм (артык чуар, бизәкле, күперенке стиль).

**ЭВФУИСТИ'ЧЕСКИЙ** *лит.*— эвфуистик, артык чуар, бизәкле, күперенке, кабарынкы (стиль турында).

**ЭГАЛИТАРИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *социол.* — эгалитаризм (җитештерү средстволарына хосусый милек принцибын җәелдергән хәлдә, милек ягыннан тигезлек булдыруны алга сөрүче вак буржуаз утопик теорияләр).

**ЭГАЛИТАРИ'СТ** *м. социол.* — эгалитарист, эгалитаризм тарафдары.

**ЭГАЛИТА'РНЫЙ** *книж.*— эгалитар, милек ягыннан тигезләүгә нигезләнгән; *эгалитарная утопия* — эгалитар утопия.

**ЭГЕ', ЭГЕ-ГЕ'** *межд. разг.*— э-һе! о-һо! о-һо-һо! эге-ге! *вот это новость!* — о-һо-һо! менә бу яңалык! менә сиңа яңа хәбәр!

**ЭГИ'ДА** *ж. мн.* нет, *книж.*: **под эгидой** — эгидасы астында, химаясендә, яклавы аркасында, канаты астында; *под эгидой закона* — закон канаты астында.

**ЭГОИ'ЗМ** *м. мн.* нет — эгоизм, эгоистлык, үз-үзеңне ярату (шәхси интересларны җәмгыять интересларыннан өстен кую).

**ЭГОИ'СТ** *м.*— эгоист, үз-үзен яратучы кеше (шәхси интересларны беренче планга куючы кеше, үз интересларын гына күзәтүче кеше).

**ЭГОИСТИ'ЧЕСКИЙ** — эгоизм...-ы; эгоистлык...-ы; эгоистик, эгоистларча..., эгоистларга хас, үз-үзеңне ярату...-ы, үз-үзен яратучыларча..., үз-үзен яратучыларга хас; *эгоистическое чувство* — эгоистлык хисе; *эгоистический поступок* — эгоистларча эш итү.

**ЭГОИСТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — эгоистлык, үз-үзен яратучылык, шәхси интересларны беренче планга кую.

**ЭГОИСТИ'ЧНЫЙ** — к. эгоистический.

**ЭГОИ'СТКА** *ж.*— к. эгоист.

**ЭГОТИ'ЗМ** *м. мн.* нет — эготизм (үзен турында бик югары фикердә булу, үз шәхесенең әһәмиятен күпертү).

**ЭГОЦЕНТРИ'ЗМ** *ж. мн.* нет, *книж.* — эгоцентризм (иң чик дәрәҗәдәге индивидуализм, үз-үзенә дөньяда мин генә дип карау).

**ЭГРЕ'Т** *м.*, **ЭГРЕ'ТКА** *ж.*— эгрет (хатын-кыз баш киемендә өскә калкып тора торган каурый яки башка берәр төрле бизәк).

**Э'ДАК** *нареч. простореч.*— к. этак.

**Э'ДАКИЙ** *простореч.*— к. этакий.

**ЭДЕЛЬВЕ'ИС** *м.*— эдельвейс (Альп тауларында үсә торган күпьеллык үсемлек).

**ЭДЕ'М** *м. мн.* нет — 1. *книж.-поэт.* җәннәт, оҗмах; 2. *перен. книж.* бай урын, табигатькә бай урын.

**ЭДИ'КТ** *м. истор.*— эдикт, фәрман (югары власть указы); *королевский эдикт* — король фәрманы.

**ЭДИ'Л** *м. истор.*— эдил (борынгы Римдә трибун ярдәмчесе вазифасын үтәүче хезмәткәр).

**ЭДИЦИО'ННЫЙ: эдиционная техника** *филол.*— эдицион техника (аерым текстны фәнни басма өчен хәзерләү алымнары һәм кагыйдәләре).

**ЭЖЕ'КТОР** *м. тех.*— эжектор (пар көче белән эшли торган насос); *эжектор для очистки судна от мусора* — судноны чүпчардан чистарту эжекторы.

**ЭЗО'П** *м.*— эзоп (1. *ирон. устар. разг.* мәгънәсез кеше, сәер кеше, буталчык тел белән сөйләшүче кеше; 2. *публиц.* кинаяле тел белән язучы кеше, кинаял кулланып язучы кеше; күңелсез хәлләрдән, цензура эзәрлекләвеннән качу өчен).

**ЭЗО'ПОВСКИЙ, ЭЗО'ПСКИЙ** — эзоп...-ы; кинаяләргә бай, читләтеп әйтүләргә бай; *эзоповский язык* — эзоп теле, кинаяләргә бай тел.

**ЭЗОТЕРИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — эзотерик, серле, яшерен, аерым кешеләргә генә аңлашыла торган; *эзотерическое значение какого-нибудь обряда* — нинди дә булса йоланың серле ягы.

**ЭЙ** *межд.* — 1. әй; *эй, кто там?* — әй, кем анда? 2. әй, кара аны, сак бул; *эй, не женися, Шприх!* (Лермонтов) — кара аны, өйләнмә, Шприх!

**ЭЙХИНИ'Н** *м. мн.* нет — эйхинин (хининның бер төре).

**ЭК** *простореч.*— 1. о-һо, менә, әнә кара, кара син аны; *эк что выдумал!* — о-һо нәрсә уйлап чыгарган; 2. *нареч.* кара ничек, менә ничек, әнә ничек; *эк я умаялся!* — кара ничек талчыкканмын!

**ЭКВА'ТОР** *м.*— экватор (1. *геогр. астр.* җир шарын һәм күк сферасын көньяк һәм төньяк ярымшарларга бүлә торган уйланма сызык; *земной экватор* — җир экваторы; 2. *спец.* шарны урталай бүлүче һәрбер түгәрәк).

**ЭКВАТОРИА'Л** *м. астр.* — экваториал (күк сферасындагы һәрбер яктырткыч җисемнең күк экваторына карата торышын билгеләргә ярдәм итүче астрономик инструмент).

**ЭКВАТОРИА'ЛЬНЫЙ** *науч.* — 1. экваториаль, экватор...-ы; *экваториальный круг*— экваториаль түгәрәк, экватор түгәрәге; 2. экваториаль, экватордагы, экватор тирәсендәге; *экваториальные страны* — экватор тирәсендәге илләр.

**ЭКВИВАЛЕ'НТ** *м.*— эквивалент (1. *книж.* берәр нәрсәгә һәр яктан тиңдәш була алырлык икенче бер нәрсә; 2. *экон.* берәр товарның кыйммәтен билгеләүче икенче бер товар; 3. *хим.* водородның бер өлеше белән кушыла торган яки шуны өлешне аерым кушылмаларда алмаштыра торган элемент микъдары).

**ЭКВИВАЛЕ'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— эквивалентлык, тиңдәшлек, тиң булучылык, тулысы белән алмаштыра алучылык.

**ЭКВИВАЛЕ'НТНЫЙ** *книж.* — эквивалент..., эквивалентлы, тиңдәш, тиң булган, тулысы белән алмаштыра алучы; *эквивалентные уравнения* (*мат.*)— эквивалент тигезләмәләр; *эти величины эквивалентны* — бу зурлыклар эквивалентлылар.

**ЭКВИВОКА'ЦИЯ** *ж.* — эквивокация, ике мәгънәлелек, аңлашылмаучылык (ике мәгънәле сүзне яки тәгъбирне урынсыз куллану аркасында килеп чыккан аңлашылмаучылык).

**ЭКВИЛИБРИ'РОВАТЬ** *несов. спец.*— эквилибристика белән шөгыльләнү.

**ЭКВИЛИБРИ'СТ** *м.*, **ЭКВИЛИБРИ'СТКА** *ж. спец.*— эквилибрист (эквилибристика белән шөгыльләнүче цирк артисты).

**ЭКВИЛИБРИ'СТИКА** *ж. мн.* нет — эквилибристика (1. *спец.* иң читен хәлләрдә дә, мәсәлән, корыч аркан өстендә тигезлек саклау осталыгына корылган күнегүләр; 2. *перен.* тапкырлык, үткенлек, чаялык; *умственная эквилибристика* — акыл үткенлеге).

**ЭКВИПОТЕНЦИА'ЛЬНЫЙ** *физ.* — эквипотенциаль, бер үк потенциаллы, тиң потенциаллы; *эквипотенциальные поверхности* — эквипотенциаль өслекләр.

**ЭКЗАЛЬТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— экзальтация, чиксез шатлыклы хәл, чиксез күтәренке халәт; *находиться в экзальтации* — үз-үзенне чиксез шат хис итү.

**ЭКЗАЛЬТИ'РОВАННОСТЬ** *ж. книж.*— экзальтация хәлендә булу, чиксез шат булу, күтәренке хәлдә булу.

**ЭКЗАЛЬТИ'РОВАННЫЙ** *книж.* — 1. экзальтация хәлендәге, чиксез шатлыклы хәлдәге; *экзальтированный человек* — экзальтация хәлендәге кеше; 2. экзальтация аркасында килеп чыккан, экзальтациядән барлыкка килгән, экзальтация белән сугарылган, чиксез шатлык белән сугарылган; *экзальтированный взор* — экзальтацияле караш, чиксез шатлык белән сугарылган караш.

**ЭКЗА'МЕН** *м. книж.* — экзамен, сынау, имтихан; *сдать экзамен* — имтихан тапшыру.

**ЭКЗАМЕНАЦИО'ННЫЙ** — экзаменацион, экзамен...-ы, имтихан...-ы; *экзаменационная комиссия* — имтихан комиссиясе.

**ЭКЗАМЕНОВА'ТЬ** *несов.* — экзамен алу, имтихан алу, сынау алу; *экзаменовать студента* — студенттан имтихан алу.

**ЭКЗАМЕНОВА'ТЬСЯ** *несов.*— **1.** экзамен тапшыру (бирү, тоту, үтү), имтихан тапшыру (бирү, тоту, үтү), сынау тапшыру (тоту, үтү); **2.** *страд.* экзамен тапшырылу (бирелү, тотылу) имтихан тапшырылу (бирелү, тотылу).

**ЭКЗАМЕНА'ТОР** *м.*— экзаменатор, экзамен алучы, имтихан алучы, сынау алучы.

**ЭКЗАМЕНА'ТОРСКИЙ** — экзаменатор ...-ы, имтихан алучы...-ы, сынау алучы...-ы; *экзаменаторские обязанности* — экзаменатор вазифалары.

**ЭКЗА'РХ** *м.*— экзарх (**1.** *истор.* борынгы Грециядә гыйбадәтханәдәге каһиннәр — жрецлар башлыгы; **2.** *истор.* Византия императорының Рим биләмәләрендәге наместнигы; **3.** *церк. истор.* православие динендә мөстәкыйль чиркәү башлыгы).

**ЭКЗЕГЕ'ЗА** *ж. мн.* нет, *спец.*— экзегеза (**1.** дин сабагында бирәр текстның аңлатмасы, шәрхе; **2.** филологик аңлатма).

**ЭКЗЕГЕ'Т** *м. спец.*— экзегет, экзегетика белгече.

**ЭКЗЕГЕ'ТИКА** *ж. мн.* нет, *спец.*— экзегетика, экзегеза кагыйдәләре һәм алымнары.

**ЭКЗЕГЕТИ'ЧЕСКИЙ** *спец.* — экзегетик, экзегетика...-ы; *экзегетический приём* — экзегетика алымы.

**ЭКЗЕКВАТУ'РА** *ж. мн.* нет, *дипл.*— экзекватура (берәр хөкүмәтнең чит ил дәүләте консулына биргән таныклыгы).

**ЭКЗЕКУ'ТОР** *м. офиц. дореВол.*— экзекутор (нинди дә булса канцеляриядә, идарәдә хуҗалык һәм тәртип саклау эшләрен алып баручы чиновник).

**ЭКЗЕКУ'ЦИЯ** *ж.* — экзекуция (**1.** тән җәзасы; **2.** *офиц. устар.* суд хөкемен, аерым алганда, үлем, тән җәзасын гамәлгә ашыру; **3.** *публиц.* массовый төстә җәзалау, мәсәлән, революцион баш күтәрүчеләрне ату һ. б.).

**ЭКЗЕ'МА** *ж. мед.*— экзема, тимрәү (кычытулы тире авыруы); *болеть экземой* — экзема белән авыру.

**ЭКЗЕМАТО'ЗНЫЙ** *мед.*— экзематоз, экзема...-ы, экземага хас; *экзематозное явление* — экзема күренеше.

**ЭКЗЕМПЛЯ'Р** *м.*— **1.** экземпляр, нөсхә, данә; *переписать в двух экземплярах* — ике нөсхәдә күчереп язу; **2.** төр, вәкил; *редкий экземпляр пальмы* — пальманың сирәк очрый торган бер төре.

**ЭКЗЕРЦИ'ЦИИ** *мн. устар.*— экзерцицияләр, күнегүләр (музыкаль, хәрби һ. б. күнегүләр); *играть экзерциции на рояле* — рояльдә күнегүләр башкару.

**ЭКЗОГА'МИЯ** *ж. мн.* нет, *этнол.* — экзогамия (үз кабиләсеннән, үз ыруыннан, үз социаль группасыннан хатын алуны тыя торган йола).

**ЭКЗОГА'МНЫЙ** *этнол.* — экзогамиягә нярүче, экзогамияне саклаучы, экзогамияне яклаучы; *экзогамное племя* — экзогамияне саклаучы кабилә.

**ЭКЗО'Т** *м. спец.*— экзот (экзотик үсемлек яки хайван).

**ЭКЗОТЕРИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— экзотерик, бөтен кешеләргә дә аңлаешлы, серле булмаган.

**ЭКЗО'ТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— экзотика (чит һәм ерак илләргә, күбесенчә җылы якларга хас булган, ләкин башка ил кешесенә сәер һәм кызыклы булып күренгән әйберләр, күренешләр һ. б.); *увлекаться экзотикой* — экзотика белән мавыгу.

**ЭКЗОТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — **1.** экзотик, чит, ят, чит җир ...-ы; эссе як...-ы; *экзотические растения* — экзотик үсемлекләр; *экзотический быт* — чит җир көнкүреше; **2.** экзотик, гаҗәп, әкәмәт, кызык, сәер; *экзотический костюм* — сәер костюм; *экзотический танец* — әкәмәт танец.

**ЭКЗОТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — экзотиклык, гаҗәплек, әкәмәтлек, сәерлек; *экзотичность костюма* — костюмның сәерлеге.

**ЭКЗОТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. экзотический 2.

**ЭКИВО'КИ** *мн.*— ике мәгънәле сөйләү, ике мәгънәле сиздереп куюлар, мәгънәне боргалаулар, киналәр; *оставьте ваши экивоки!* — ике мәгънәле сөйләвегезне ташлагыз әле!

**Э'КИЙ** *простореч.*— кара инди, инди, менә инди, әнә инди; *экий ты неугомонный!* — нинди тынычсыз кеше син! *экие нежности!* — кара нинди назланулар!

**ЭКИПА'Ж** *м.*— экипаж (**1.** җиңел арба, повозка; **2.** *мор. ав. воен.* корабль (самолёт, танк) командасы; **3.** *воен. мор.* диңгез пехотасының ярдагы хәрби берәмлеге).

**ЭКИПА'ЖНЫЙ** — экипаж...-ы; *экипажный командир* — экипаж командиры.

**ЭКИПИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. офиц.* — кирәк-ярак белән тәэмин итү, кирәк-яракны булдыру, киендерү, җиһазландыру; *экипировать бойцов* — сугышчыларны кирәк-ярак белән тәэмин итү.

**ЭКИПИ'РОВАТЬСЯ** *несов.* — кирәк-ярак белән тәэмин ителү, кирәк-ярак булдырылу, киендерелү, җиһазландырылу.

**ЭКИПИРО'ВКА** *ж. мн.* нет, *офиц.* — **1.** *(действие)* кирәк-ярак белән тәэмин итү (ителү), кирәк-ярак булдыру (булдырылу), киендерү, киендерелү, җиһазландыру, җиһазландырылу; **2.** кирәк-ярак, кием-салым, азык-төлек.

**Э'ККЕР** *м. геодез.*— эккер (җир өстендә билгеле зурлыктагы почмаклар үлчәп салу өчен кулланыла торган инструмент).

**ЭКЛЕКТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *устар. книж.*— эклектизм (бергә кушылуы мөмкин булмаган төрле карашларны фәнни хезмәттә, иҗатта механик рәвештә бергә кушу, прин-

цип-сызлык; *эклектизм в философии* — философиядә эклектизм.

**ЭКЛЕ'КТИК** *м. книж.*— эклектик (эклектизмны алга сөрүче, эзлексезлек тарафдары, принципиаль җирлеге булмаган кеше).

**ЭКЛЕ'КТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.*— эклектика (эклектик булган барлык нәрсә, эзлексезлек белән сугарылган барлык нәрсә, эклектизм).

**ЭКЛЕКТИЦИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — к. эклектизм.

**ЭКЛЕКТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — эклектик, эклектизм...-ы, эклектизм (эзлексезлек) белән сугарылган; *эклектическая философия* — эклектик философия.

**ЭКЛЕКТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— эклектиклык, эклектизм (эзлексезлек) белән сугарылганлык.

**ЭКЛЕКТИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. эклектический.

**ЭКЛИ'МЕТР** *м. геодез.*— эклиметр (аерым бер урындагы җир өсте сызыгының горизонтка карата авышлыгын якынча билгеләү приборы).

**ЭКЛИ'ПТИКА** *ж. астр.*— эклиптика (күк гөмбәзендә кояшның ел буе хәрәкәт итүен күрсәткән уйланма сызык яки җирнең кояш тирәсендә әйләнү сызыгы).

**ЭКЛО'ГА** *ж. лит.*— эклога (идиллия характерындагы шигырь).

**Э'КО** *простореч. обл.*— к. эк.

**Э'КОЙ** *простореч.* — к. экий.

**ЭКОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет, *биол.*— экология (биологиядә организмнарның тирәлек белән үзара мөнәсәбәтен өйрәнүче бүлек).

**ЭКОНО'М** *м.*— эконом (1. хуҗа, йорт хуҗасы, хуҗалыкчыл кеше, яхшы хуҗа; 2. *устар.* хуҗалык эшләрен идарә итүче хезмәткәр, хуҗалык мөдире; 3. *устар.* к. экономист 1).

**ЭКОНОМИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит. истор.*— экономизм (XIX йөз ахырында рус социал-демократлары арасында барлыкка килгән оппортунистик агым; бу агым эшчеләр сыйныфы самодержавиене бәреп төшерү һәм үзенә политик хокук яулап алу өчен түгел, бары тик үзенең экономик хәлен яхшырту өчен генә көрәшергә тиеш дип өйрәтә, пролетариат партиясенең җитәкче ролен инкарь итә).

**ЭКОНО'МИКА** *ж. мн.* нет — экономика (1. җәмгыятьнең хуҗалык төзелеше, хуҗалык тормышы; *экономика социализма* — социализм экономикасы; 2. берәр эшнең хуҗалык ягы; *экономика сельского хозяйства* — авыл хуҗалыгы экономикасы; 3. хуҗалык тармагының берәр өлкәсен өйрәнүче фән).

**ЭКОНОМИ'СТ** *м.*— экономист (1. экономик фәннәр белгече, галиме, җәмгыятьнең хуҗалык тормышын өйрәнүче белгеч, галим; 2. экономика (хуҗалык) мәсьәләләре белән шөгыльләнүче хезмәткәр, белгеч; *работать экономистом в тресте* — трестта экономист булып эшләү; 3. *полит. истор.* экономизм тарафдары, экономизмны яклаучы).

**ЭКОНО'МИТЬ** *несов.*—1. экономия ясау, экономить итү, саклап (исәпләп) тоту, әрәм-шәрәм итмәү, исраф итмәү; *экономить деньги* — акчаны саклап тоту; *машины экономят труд* — машиналар хезмәткә экономия ясыйлар; 2. янга калдыру, (экономия ясап) файда күрү, (саклап, исәпләп тотып) файда итү; *экономить на материалах* — материалларга экономия ясап файда күрү.

**ЭКОНО'МИТЬСЯ** *несов. страд.*— экономия ясалу, саклану, янга калу; *благодаря электричеству экономится топливо* — электр кулланудан ягулыкка экономия ясала.

**ЭКОНОМИ'ЧЕСКИЙ** — 1. экономик; *экономический кризис* — экономик кризис; *экономическая география* — экономик география; 2. *книж. устар.* файдалы, отышлы, бәрәкәтле, экономияле, уңайлы, җайлы (хуҗалык ягыннан); *экономический способ стирки* — кер юуның файдалы ысулы. ◇ **Экономический материализм** — экономик материализм (иҗтимагый үсешнең бердәнбер көче экономик факторларда дип, тарихи процессны берьяклы, механистик аңлатучы агым). **Экономические крестьяне** *истор.*— экономик крестьяннар (Россиядә 1764 елга кадәр чиркәүләр һәм монастырьлар кул астында булып, соңыннан „рухани эшләрнең экономия коллегиясе" карамагына күчерелгән крестьяннар).

**ЭКОНОМИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— файдалылык, отышлылык, бәрәкәтлелек, экономиялелек (хуҗалык ягыннан).

**ЭКОНОМИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. экономический 2.

**ЭКОНО'МИЯ** *ж.*— экономия (1. *дореВол.* капиталистик типтагы эре алпавыт имениесе; 2. *офиц. дореВол.* авыл хуҗалыгы эшләрен идарә итүче кайбер учреждениеләр; *экономия духовных дел* — рухани эшләр экономиясе (экономик крестьяннарны идарә итүче учреждение); 3. сак тотучылык, хәстәрле булу, сакчыл булу, әрәм-шәрәм итмәү, исәпләп эш итү, исраф итмәү; *режим экономии* — экономия режимы; 4. файда, отыш, табыш; *мы добились большой экономии в топливе* — без ягулык буенча бик зур экономия ясадык).

**ЭКОНО'МКА** *ж. устар.*— к. эконом 2.

**ЭКОНО'МНИЧАТЬ** *несов. разг. неодобр.*— саранлану, карунлану.

**ЭКОНО'МНОСТЬ** *ж. мн.* нет — исәпләп (хисаплап) торучанлык, бәрәкәтчеллек, бәрәкәтлелек, сакчыллык, экономияле булу, экономиялелек; *экономность расходов* — расходларның экономиялелеге.

**ЭКОНО'МНЫЙ** — исәпләп (хисаплап) тотучан, әрәм-шәрәм итмәүчән, экономия ясаучан, сакчыл, экономияле; *экономный хозяин* — исәпләп тотучан хуҗа, экономияле (экономия ясаучан) хуҗа.

**ЭКРА'Н** *м.*— экран (1. мич эссесеннән, тәрәзәдән төшкән яктылыктан саклау өчен куела торган ышыклавыч, каплавыч; 2. *физ. тех.* электр приборларын, аппа-

ратларны тышкы тәэсирләрдән саклау өчен махсус каплавыч; 3. кинокартина күрсәтелә торган ак полотно, акка буялган стена һ. б.; 4. *перен. только ед.* кино күрсәтү, кино сәнгате; *звезда экрана* — кино сәнгате остасы, йолдызы).

**ЭКРАНИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — экранлаштыру, кинода (экранда) күрсәтү өчен яраклаштыру; *экранизация новеллы* — новелланы экранлаштыру.

**ЭКРАНИЗИ'РОВАННЫЙ** — экранлаштырылган, кинода (экранда) күрсәтү өчен яраклаштырылган.

**ЭКРАНИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — экранлаштыру, кинода (экранда) күрсәтү өчен яраклаштыру; *экранизировать роман* — романны экранлаштыру.

**ЭКРАНИЗИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — экранлаштырылу, кинода (экранда) күрсәтү өчен яраклаштырылу.

**ЭКРАНИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.* — к. экранизировать

**ЭКРАНИЗОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.* — к. экранизироваться.

**ЭКРАНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. физ. тех.* — металл каплавыч белән ышыклау, каплап кую (тышкы тәэсирләрдән саклау өчен); *экранировать прибор* — приборны металл каплавыч белән каплау.

**ЭКРАНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. физ. тех.* — каплавыч белән каплану, каплап куелу.

**ЭКС** *м. истор.* — к. экспроприация 2.

**ЭКС** *офиц.* — экс (берәр званиене, вазифаны белдерүче исем алдына кушылып „элекке", „әүвәлге" мәгънәсен бирә торган алкушымча, мәсәлән, *экс-президент* — элекке президент, *экс-директор* — элекке директор).

**ЭКСГА'УСТЕР, ЭКСГА'УСТОР** *м. тех.* — эксгаустер, эксгаустор (предприятиеләрд тузан, пар, газ һ. б. суыргыч вентилятор).

**ЭКСИКА'ТОР** *м. спец.* — эксикатор (препаратларны корыту, киптерү приборы).

**ЭКСИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.* — эксикация, корыту, киптерү.

**ЭКСКАВА'ТОР** *м.* — экскаватор (1. *тех.* җир казу эшләрен башкару өчен махсус машина; 2. *мед.* организмдагы куышлыкларны кыру өчен кулланыла торган хирургик инструмент).

**ЭКСКАВА'ТОРЩИК** *м.* — экскаваторчы, экскаваторда эшләүче.

**ЭКСКРЕМЕ'НТЫ** *ед.* нет, *книж.* — тизәк.

**ЭКСКУ'РС** *м. книж.* — экскурс (икенче дәрәҗәдәге мәсьәләне яктырту максатыннан чыгып, тикшерелә торган төп темадан читкә китү; *примечание разрослось в целый экскурс* — искәрмә тулы бер экскурска үсеп китте.

**ЭКСКУРСА'НТ** *м.*, **ЭКСКУРСА'НТКА** *ж.* — экскурсант, экскурсиядә катнашучы.

**ЭКСКУРСА'НТСКИЙ** — экскурсант...-ы, экскурсантлар ...-ы; *экскурсантский билет* — экскурсант билеты; *экскурсантский вагон* — экскурсантлар вагоны.

**ЭКСКУРСИО'ННЫЙ** — экскурсион, экскурсия...-ы; *экскурсионная база* — экскурсион база; *экскурсионный план* — экскурсия планы.

**ЭКСКУ'РСИЯ** *ж.* — экскурсия (1. фәнни танышу яки күңел ачу максаты белән коллектив рәвештә сәфәргә чыгу, берәр җиргә бару; 2. *перен. разг. шутл.* берәр нәрсәне искә төшерү; *позвольте мне сделать небольшую экскурсию в прошлое* (Салтыков-Щедрин) — рөхсәт итегез миңа үткәнгә кечкенә генә экскурсия ясап алырга; 3. экскурсантлар; *приехала экскурсия* — экскурсия килде, экскурсантлар килде).

**ЭКСКУРСОВО'Д** *м.* — экскурсовод (1. экскурсия җитәкчесе; 2. музейда карар өчен куелган әйберләрне экскурсантларга күрсәтеп һәм аңлатып йөрүче).

**ЭКСКУРСОВО'ДНЫЙ, ЭКСКУРСОВО'ДЧЕСКИЙ** — экскурсоводлар...-ы, экскурсия җитәкчеләре...-ы; *экскурсоводческие курсы* — экскурсоводлар курсы.

**ЭКСЛИ'БРИС** *м.* — экслибрис (китап хуҗасының исеме язылган, гадәттә художестволы башкарылган һәм тышлыкның эчке ягына ябыштырыла торган кәгазь, ярлык); *художественный экслибрис* — художестволы экслибрис.

**ЭКСПАНСИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — 1. экспансивлык, үз-үзеңне тыя алмаучылык; *экспансивность характера* — характерның экспансивлыгы; 2. экспансив характер, тотнаксыз характер.

**ЭКСПАНСИ'ВНЫЙ** *книж.* — экспансив, үзен тыя алмый торган, тойгыларын тыя алмый торган; *экспансивный человек* — тойгыларын тыя алмый торган кеше.

**ЭКСПАНСИОНИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *полит.* — экспансионизм, экспансиягә омтылу (дәүләт чикләрен көч белән киңәйтергә омтылу, империалистик баскынчылык политикасы).

**ЭКСПАНСИОНИ'СТ** *м. полит.* — экспансионизм тарафдары, экспансионизмны яклаучы кеше.

**ЭКСПА'НСИЯ** *ж. мн.* нет — экспансия (1. *книж.* киңәйтү, нәрсәне дә булса элекке чигеннән артыграк җәелдерү; 2. *полит.* дәүләт чикләрен көч белән киңәйтү, империалистик дәүләтнең яңа җирләр басып алырга омтылуы).

**ЭКСПАТРИА'НТ** *м.*, **ЭКСПАТРИА'НТКА** *ж. офиц.* — экспатриант, экспатриация ясаучы кеше, экспатриациягә дучар булган кеше (ватаннан сөрелгән яки үз ихтыяры белән ватанын ташлап киткән кеше).

**ЭКСПАТРИА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *офиц.* — экспатриация (ватаныннан сөреп җибәрү яки үз ихтыяры белән ватаныннан китү).

**ЭКСПАТРИИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. офиц.* — экспатриацияләү, экспатриация ясау, ватаннан сөрү.

**ЭКСПАТРИИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. офиц.* — экспатриацияләнелү, экспатриация ясалу, ватаныннан сөрелү.

**ЭКСПЕДИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. офиц.*

*торг.*— тиешле урынына җибәрү, озату (мәсәлән, товарны, корреспонденцияне).

**ЭКСПЕДИ'РОВАТЬСЯ** *несов.офиц. торг.*— тиешле урынына җибәрелү, озатылу, таратылу.

**ЭКСПЕДИ'ТОР** *м.*— экспедитор (**1.** *офиц. торг.* тиешле урынына җибәреп, таратып торучы кеше; **2.** *дореввол.* кайбер хөкүмәт учреждениеләрендә бүлек мөдире).

**ЭКСПЕДИ'ТОРСКИЙ** — экспедитор...-ы. экспедиторлар...-ы; *экспедиторская работа* — экспедитор хезмәте.

**ЭКСПЕДИЦИО'ННЫЙ** — экспедицион, экспедиция...-ы; *экспедиционная контора*— экспедицион контора, экспедиция конторасы.

**ЭКСПЕДИ'ЦИЯ** *ж.*—экспедиция (**1.** *только ед. офиц. торг.* тиешле урынына җибәрү, тарату, озату; **2.** *офиц. торг.* тиешле урынына җибәрү, озатып тору учреждениесе; *газетная экспедиция* — газета экспедициясе; **3.** махсус максат белән оештырылган сәяхәт, сәфәр; *научная экспедиция*— фәнни экспедиция; **4.** экспедициягә чыккан кешеләр коллективы; *экспедиция из двадцати человек* — егерме кешедән торган экспедиция).

**ЭКСПЕРИМЕ'НТ** *м. книж.*— **1.** эксперимент, фәнни тәҗрибә; *произвести эксперимент* — эксперимент ясау; **2.** тәҗрибә, сынау.

**ЭКСПЕРИМЕНТА'ЛЬНЫЙ** — **1.** эксперименталь, тәҗрибәгә нигезләнгән; *экспериментальный метод* — эксперименталь метод; **2.** эксперименталь, берәр максат өчен (тәҗрибә өчен) махсус булдырылган; *экспериментальный туберкулёз* — махсус булдырылган туберкулёз.

**ЭКСПЕРИМЕНТА'ТОР** *м. книж.*— экспериментатор, фәнни тәҗрибә ясаучы, тәҗрибәче; *он был хорошим экспериментатором* — ул бик яхшы экспериментатор иде.

**ЭКСПЕРИМЕНТИ'РОВАТЬ** *несов. книж.*— эксперимент ясау, фәнни тәҗрибә ясау, тәҗрибә ясау, тәҗрибә үткәрү; сынау үткәрү, сынап карау.

**ЭКСПЕ'РТ** *м.*— эксперт (берым эш яки мәсьәлә буенча махсус белем сорый торган дәгъваны чишү яки шуның турында үзенең фикерен әйтү өчен чакырылган галим, белгеч); *комиссия экспертов* — экспертлар комиссиясе.

**ЭКСПЕРТИ'ЗА** *ж.*— экспертиза (нинди дә булса эш яки мәсьәләнең экспертлар тарафыннан билгеле бер нәтиҗә чыгару өчен каралуы, тикшерелүе); *научная экспертиза* — фәнни экспертиза.

**ЭКСПЕ'РТНЫЙ** — эксперт...-ы, экспертлар...-ы; *экспертная комиссия* — экспертлар комиссиясе.

**ЭКСПИРАТО'РНЫЙ** *науч.*— экспиратор сулыш...-ы, экспирациягә нигезләнгән; *экспираторное ударение* — сулыш басымы.

**ЭКСПИРА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *науч.*— экспирация, сулыш, сулыш чыгару, сулышны тышка чыгару (мәсәлән, сөйләгәндә).

**ЭКСПЛАНТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *биол.*— эксплантация (организмның берәр тукымасын күчереп утырту).

**ЭКСПЛИКА'ЦИЯ** *ж. спец.*— экспликация (**1.** *только ед.* аңлатма; **2.** аңлатма язу, аңлатма текст; күбесенчә карталарда, планнарда кулланыла торган шартлы билгеләр аңлатмаларының тексты).

**ЭКСПЛИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. спец.*— шартлы билгеләргә аңлатма бирү, аңлатма текст бирү.

**ЭКСПЛИЦИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— шартлы билгеләргә аңлатма бирелү, аңлатма текст бирелү.

**ЭКСПЛОЗИ'ВНЫЙ** *лингв.*— эксплозив, шартлаулы; *эксплозивные согласные* — шартлаулы тартыклар.

**ЭКСПЛУАТА'ТОР** *м.*, **ЭКСПЛУАТА'ТОРКА** *ж.*— эксплуататор, эксплуатацияләүче (**1.** кеше хезмәтенең нәтиҗәсен үзләштерүче капиталист, кулак, алпавыт, житештерү средстволары хуҗасы; **2.** берәр нәрсәдән яки кеше көченнән үз интересларыннан чыгып файдаланучы; *эксплуататор чьей-нибудь доверчивости* — берәр кешенең ышанычыннан файдаланучы).

**ЭКСПЛУАТА'ТОРСКИЙ** — эксплуататор..., эксплуататорлар...-ы, изүче, изүчеләр...-ы; *эксплуататорские классы в буржуазном обществе* — буржуаз җәмгыятьтә эксплуататор сыйныфлар.

**ЭКСПЛУАТАЦИО'ННИК** *м. спец.*— эксплуатационник, эксплуатацияләүче, эшләтүче (нәрсәне дә булса эксплуатацияләү, практик файдалану буенча эшләүче кеше); *эксплуатационник воздушной линии*— һава юлын эксплуатацияләүче.

**ЭКСПЛУАТАЦИО'ННЫЙ** — эксплуатацион, эксплуатация...-ы; *эксплуатационные работы* — эксплуатацион эшләр, эксплуатация эшләре.

**ЭКСПЛУАТА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — эксплуатация (**1.** *социол. полит.* житештерү средстволары хуҗасының кеше хезмәтен үзләштерүе, кеше хезмәтеннән файдалану, табыш алу, эксплуатацияләү; **2.** берәр нәрсәдән практик файдалану, нәрсәне дә булса практик үзләштерү, эшкә җибәрү; *эксплуатация воздушной линии* — һава юлыннан практик файдалану; **3.** *перен.* кемнән яки нәрсәдән дә булса үз интересларыннан чыгып файдалану, эксплуатацияләү; *эксплуатация доверия* — кемнең дә булса ышанычыннан файдалану; **4.** *спец.* транспорт чараларын пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен файдалану; *отдел эксплуатации* — эксплуатация бүлеге).

**ЭКСПЛУАТИ'РОВАТЬ** *несов.*— к. эксплуатация 1, 2.

**ЭКСПЛУАТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.*— эксплуатацияләнү; эксплуатация ясалу, файдалану, үзләштерелү.

**ЭКСПОЗЕ'** *ср. нескл. офиц.*— экспозе (**1.** берәр документның кыскача аңлатмасы, берәр документтан алынган өземтә; **2.** хөкүмәт вәкиленең парламентта агымдагы политиканың берәр мәсьәләсе буенча кыскача белдерүе).

**ЭКСПОЗИТУ'РА** *ж. полит.*— экспозитура (берәр дәүләтнең чит дәүләттәге агентурасы).

**ЭКСПОЗИЦИО'ННЫЙ** *спец.*— экспозицион, экспозиция...-ы; *экспозиционный план* — экспозиция планы.

**ЭКСПОЗИ'ЦИЯ** *ж.*— экспозиция (1. *лит. муз.* әдәби яки музыкаль әсәрнең сонга таба үстерелә торган мотивларын эченә алган кереш өлеше, мөкаддимәсе; 2. *спец.* карау өчен билгеләнгән предметларның мәгълүм тәртиптә тезелүе, куелуы һ. б.; 3. *спец.* шул тәртиптә тезелгән предметларның үзләре; *удачная экспозиция* — уңышлы экспозиция; 4. *фот.* яктылыкта тотып алу, яктыртып алу; *снимать с длительной экспозицей* – озак экспозиция белән рәсемгә төшереп алу).

**ЭКСПОНА'Т** *м.*— экспонат (күргәзмәгә, музейларга куела торган әйберләр); *выставочный экспонат* — күргәзмә экспонаты.

**ЭКСПОНЕ'НТ** *м.*— экспонент (1. *спец.* экспонат иясе, күргәзмәгә экспонат куючы кеше яки оешма; 2. *мат.* дәрәҗә күрсәткече).

**ЭКСПОНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. *спец.* күргәзмәгә кую, күрсәтергә кую; *экспонировать картину* — картинаны күргәзмәгә кую; 2. *перен. шахм.* һөҗүм астына кую, берәр шахмат фигурасы белән дошман сугып алырлык итеп йөрү; *белые экспонировали своего ферзя* — аклар ферзьләрен һөҗүм астына куйдылар; 3. *фот.* яктылык йогынтысына кую, яктылык бирү, яктырту (фотография пластинкасын).

**ЭКСПОНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.*— күргәзмәгә куелу, күрсәтергә куелу.

**Э'КСПОРТ** *м. мн.* нет, *экон.*— экспорт, чит илгә чыгару; *экспорт хлеба* — чит илгә ашлык чыгару.

**ЭКСПОРТЁР** *м. экон.*— экспортёр, товарларны чит илгә чыгаручы (кеше, оешма һ. б.).

**ЭКСПОРТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. экон.*— чит илгә чыгару (товарны, капиталны); *экспортировать хлеб* — чит илгә ашлык чыгару.

**ЭКСПОРТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. экон.*— чит илгә чыгарылу.

**Э'КСПОРТНЫЙ** *экон.*— 1. экспорт...-ы, чит илгә (товар, капитал) чыгару...-ы; *экспортные операции* — экспорт операцияләре, чит илгә товар чыгару операцияләре; 2. экспорт өчен билгеләнгән, чит илгә чыгару өчен билгеләнгән, чит илгә чыгарыла торган; *экспортный лес* — чит илгә чыгару өчен билгеләнгән агач материаллары.

**ЭКСПРЕ'СС** *м.*— экспресс (үтә тиз йөрешле поезд, пароход һ. б.); *уехать экспрессом* — экспресс белән юлга чыгу (китү).

**ЭКСПРЕССИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* - экспрессивлык, сәнгатьлелек, тәэсирлелек, тәэсир итүчәнлек, мәгънәлелек.

**ЭКСПРЕССИ'ВНЫЙ** *книж.*— экспрессив, сәнгатьле, тәэсирле, тәэсир итүчән, мәгънәле; *экспрессивная речь* — тәэсирле сөйләм.

**ЭКСПРЕССИОНИ'ЗМ** *ж. мн.* нет, *искус.*— экспрессионизм (20 йөздә Көнбатыш сәнгатендә барлыкка килеп, тышкы дөньяны кешенең субъектив хәлен, кичерешләрен чагылдыру чарасы итеп кенә карый торган реакцион идеалистик юнәлеш).

**ЭКСПРЕССИОНИ'СТ** *м. искус.*— экспрессионист, экспрессионизм тарафдары.

**ЭКСПРЕССИОНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *искус.*— экспрессионистик, экспрессионизм ...-ы; экспрессионизмга хас; *экспрессионистический стиль* — экспрессионизм стиле.

**ЭКСПРЕССИОНИ'СТСКИЙ** *искус.*— экспрессионист...-ы, экспрессионистлар ...-ы; экспрессионистларга хас, экспрессионистларча...; экспрессионизм...-ы, экспрессионистик, экспрессионизмга хас; *экспрессионистский стиль* — экспрессионистлар стиле.

**ЭКСПРЕ'ССИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— экспрессия, сәнгатьлелек, тәэсирлелек, тәэсир итүчәнлек, художестволылык, мәгънәлелек; *он спел романс с большой экспрессией* — ул романсны аеруча сәнгатьлелек белән (тәэсирле) башкарды.

**ЭКСПРО'МТ** *м. устар. книж.*— экспромт (алдан хәзерләнмичә сөйләнгән речь, кинәт, көтмәгәндә язылган шигырь, музыка әсәре, һ. б ); *удачный экспромт* — уңышлы экспромт.

**ЭКСПРО'МТОМ** *нареч. книж.*— алдан хәзерләнмичә, кинәт, көтмәгәндә, капыл гына; *произнести речь экспромтом* — алдан хәзерләнмичә речь сөйләү.

**ЭКСПРОПРИА'ТОР** *м. книж.*— экспроприатор, экспроприация эшләүче, көч белән тартып алучы; *одним из лозунгов пролетарской революции является экспроприация экспроприаторов* — пролетариат революциясенең лозунгларыннан берсе — экспроприаторларны экспроприацияләү (алпавытларны һәм капиталистларны җитештерү средстволарыннан мәхрүм итү).

**ЭКСПРОПРИА'ЦИЯ** *ж.*— экспроприация (1. *книж.* нәрсәне дә булса көч белән тартып алу, мәҗбүри рәвештә тартып алу; 2. *полит. истор.* революцион оешмаларның ихтыяҗлары өчен кораллы көч ярдәмендә дәүләт учреждениеләреннән, банклардан һ. б. кораллану әйберләре яки акча тартып алу; 3. *только ед. экон.* җитештерү средстволарыннан мәхрүм итү).

**ЭКСПРОПРИИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. экспроприацияләү, көч белән тартып алу, мәҗбүри рәвештә тартып алу; *экспроприировать капитал* —капиталны көч белән тартып алу; 2. экспроприацияләү, җитештерү средстволарыннан мәхрүм итү; *экспроприация капиталистов* — капиталистларны җитештерү средстволарыннан мәхрүм итү.

**ЭКСПРОПРИИ'РОВАТЬСЯ** *несов. книж. страд.*— экспроприацияләнү, көч белән тартып алыну; җитештерү средстволарыннан мәхрүм ителү.

**ЭКСТА'З** *м. мн.* нет — экстаз, чиктән тыш шатлану, шашып шатлану (бар нәрсәне онытгырырлык рух күтәренкелеге, үз-үзенне онытырлык дәрәҗәдә шатлану).

**ЭКСТАТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — экстаз...-ы, чиктән тыш шатлану...-ы, гаять шатлыклы, үз-үзенне онытырлык дәрәҗәдә шатлану ...-ы; *экстатическое состояние* — экстаз халәте, чиктән тыш шатлану халәте.

**ЭКСТАТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — экстаз белән сугарылган, чиктән тыш шатлык белән сугарылган.

**ЭКСТЕНСИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.* — экстенсивлык, бер урынга тупланмаган булу, таркаулык, төрле җиргә (чәчелгән) сибелгән булу.

**ЭКСТЕНСИ'ВНЫЙ** *книж.* — экстенсив, бер урынга тупланмаган, таркау, төрле җиргә чәчелгән, сибелгән. ◇ **Экстенсивное хозяйство** — экстенсив хуҗалык (хезмәтне бик аз гына куюга исәп тотып корылган һәм табигый байлыкларны бары тик ярлыландыру юлы белән үстерелә торган хуҗалык)

**ЭКСТЕ'РН** *м.* — экстерн (1. аерым уку йортында укымыйча, тиешле экзаменнарны үзлегеннән укып тапшыручы кеше; *кончить школу экстерном* — мәктәпне экстерн юлы белән тәмам итү; 2. *дореvол.* квартирада торып, ябык типтагы мәктәптә укучы; 3. *мед. дореvол.* тәҗрибә алу максаты белән берәр больницада яки учреждениедә штатта тормыйча эшләүче врач).

**ЭКСТЕРНА'Т** *м. мн.* нет, *офиц.* — экстернат (1. уку йортында үзлегеннән укып имтихан тапшыру системасы; 2. *мед. дореvол.* экстерн вазифасы, тәҗрибә туплау өчен берәр больницада яки учреждениедә штаттан тыш эшләүче врач вазифасы).

**ЭКСТЕРРИТОРИА'ЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *право* — экстерриториальлек (чит ил кешеләрен яки дипломатик агентларын урындагы законнарга буйсынудан азат итеп, аларга үз илләрендә кабул ителгән законнар нигезендә яшәргә мөмкинлек бирү хокукы); *право экстерриториальности* — экстерриториальлек хокукы.

**ЭКСТЕРРИТОРИА'ЛЬНЫЙ** *право* — экстерриториаль, экстерриториальлек хокукына ия булган; *дом посла экстерриториален* — илченең йорты экстерриториаль, илченең йорты экстерриториальлек хокукына ия.

**ЭКСТЕРЬЕ'Р** *м. мн.* нет, *спец.* — экстерьер, терлекнең тышкы төзелеше; *определение качеств лошади по экстерьеру* — атның сыйфатларын тышкы төзелешенә карап билгеләү.

**ЭКСТИРПА'ТОР** *м. с.-х.* — экстирпатор, табанлы культиватор.

**ЭКСТИРПА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.* — экстирпация (кеше организмындагы берәр әгъзаны операция юлы белән кисеп алу).

**ЭКСТРАВАГА'НТНОСТЬ** *ж. книж.* — 1. *только ед.* сәерлек, сәер булу, холыксызлык, холыксыз булу, дуамаллык, дуамал булу, җенлелек; *экстравагантность характера* — характерның дуамаллыгы; 2. дуамаллану, холыксызлану, җенләнү; *его экстравагантности становятся всё более резкими* — аның дуамалланулары һаман көчәя бара.

**ЭКСТРАВАГА'НТНЫЙ** *книж.* — сәер, гаҗәп, холыксыз, дуамал, җенле; *экстравагантный характер* — дуамал характер, дуамал холык.

**ЭКСТРАГИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов.* — 1. *спец.* суыру, суырып чыгару, суырып ташлау, алу, алып ташлау; *экстрагировать зуб* — тешне суырып ташлау; 2. *хим.* аеру, аерып чыгару, аерып алу, сыгу, сыгып алу, сыгып чыгару (билгеле бер составтан, кушылмадан берәр нәрсә эретеп, аерып чыгару); *экстрагировать жир из чего-нибудь* — берәр нәрсәдән май аерып чыгару.

**ЭКСТРАГИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. спец.* — суырылу, суырып чыгарылу, суырып ташлану, алып ташлану.

**ЭКСТРА'КТ** *м.* — 1. экстракт, сыгынты, сөземтә; *ягодный экстракт* — җиләк сыгынтысы; 2. *книж.* кыскача эчтәлек; *сделать экстракт статьи* — мәкаләнең кыскача эчтәлеген язып чыгу.

**ЭКСТРАКТИ'ВНЫЙ** *хим.* — 1. экстрактив, аерып алына торган, аерып чыгарыла торган, сыгып алына торган, сыгып чыгарыла торган; *экстрактивные вещества* — аерып алына торган матдәләр; 2. экстрактив, экстракт сыйфатларына ия булган.

**ЭКСТРА'КТОР** *м. тех.* — экстрактор, аеру аппараты, аерып алу аппараты.

**ЭКСТРА'КЦИЯ** *ж. мн.* нет, *спец.* — к. экстрагировать.

**ЭКСТРАОРДИНА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет — гадәттән тышлык, гадәттән тыш булу, сирәк очрый торганлык, сирәк очрый торган булу; *экстраординарность случая* — вакыйганың гадәттән тышлыгы.

**ЭКСТРАОРДИНА'РНЫЙ** — 1. *книж.* гадәттән тыш, сирәк очрый торган, искиткеч; *экстраординарное происшествие* — гадәттән тыш вакыйга; 2. *офиц. дореvол. только полн. формы* экстраординар, штаттан тыш, кафедрасы булмаган (гыйльми вазифа турында); *экстраординарный профессор* — экстраординар профессор.

**ЭКСТРАПОЛИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. мат.* — экстраполяцияләү, бирелгән кыйммәтләр буенча зуррак кыйммәтне табу.

**ЭКСТРАПОЛИ'РОВАТЬСЯ** *несов. мат.* — экстраполяцияләнү, бирелгән кыйммәтләр буенча зуррак кыйммәт табылу.

**ЭКСТРАПОЛЯ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мат.* — экстраполяция (берәр функциянең билгеле кыйммәтләреннән файдаланып, шушы функциядән тыш булган кыйммәтләрне табу).

**ЭКСТРЕМИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — экстремизм, иң чик карашларга, чараларга бирелүчәнлек (күбесенчә политикада).

**ЭКСТРЕМИ'СТ** *м. книж.* — экстремист, экстремизм тарафдары, иң чик карашларга, чараларга бирелүче кеше, иң чик караш-

ларны, чараларны яклаучы кеше (күбесенчә политикада).

**ЭКСТРЕМИ'СТСКИЙ** *книж.*— экстремизм...-ы, экстремизмга хас; экстремист...-ы, экстремистлар...-ы, экстремистларга хас; *экстремистская тактика* — экстремистлар тактикасы.

**Э'КСТРЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. ашыгычлык, кичектерелмәслек, кичектергесезлек; *экстренность дела* — эшнең ашыгычлыгы; 2. *разг.* ашыгыч эш, кичектерелмичә эшләнергә тиешле эш; *что за экстренность?*— нинди ашыгыч эш ул?

**Э'КСТРЕННЫЙ** — 1. ашыгыч, кичектерергә ярамый торган, кичектергесез; *экстренная помощь* — ашыгыч ярдәм; 2. гадәттән тыш, көтелмәгән; *экстренные расходы* — көтелмәгән расходлар.

**ЭКСУДА'Т** *м. мед.*— эксудат, тир (ялкынсыну вакытында вак тамырлардан тукымага яки тән куышлыкларына тир рәвешендә үтеп чыга торган сыекча).

**ЭКСУДА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— эксудация, эксудат барлыкка килү процессы.

**ЭКСЦЕНТРИА'ДА** *ж. театр.*— эксцентриада (эксцентрик алымнарга нигезләнгән театр яки цирк уены).

**ЭКСЦЕ'НТРИК** *м.*— эксцентрик (1. *тех.* машинаның әйләнү хәрәкәтен йөреш хәрәкәтенә әверелдерә торган детале; 2. *театр.* циркта, эстрадада көлке, эксцентрик номерлар башкарып, тамашачыларны көлдерүче артист).

**ЭКСЦЕНТРИЦИТЕ'Т** *м.*— эксцентриситет (1. *тех.* валга кидертелгән эксцентрик үзәге белән вал үзәге арасы; 2. *мат.* эллипс фокуслары арасы; 3. *мат.* эллипс фокуслары арасының эллипсның олы күчәре озынлыгына нисбәте).

**ЭКСЦЕНТРИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *мат.* эксцентрик, гомуми үзәккә карамаган, бер үзәккә карамаган; *эксцентрические фигуры* — бер үзәккә карамаган фигуралар; 2. *перен. книж.* гаҗәп, бик сәер, мәзәкчән, юләрсыман, кызык; *эксцентрический человек* — бик сәер кеше, кызык кеше, эксцентрик кеше; 3. *театр.* эксцентрик (тавыш һәм яктылыкның кискен үзгәрешләренә яки көлкеле алымнарга нигезләнгән); *эксцентрический номер* — эксцентрик номер.

**ЭКСЦЕНТРИ'ЧНОСТЬ** *ж. книж.*— 1. *только ед.* гаҗәплек, сәерлек, мәзәкчәнлек, юләрсыманлык, кызыклык; гаҗәп кыланыш, бик сәер кыланыш, мәзәкчән (юләрсыман, кызык) кыланыш; *что за эксцентричности?*— бу нинди юләрсыман кыланышлар?

**ЭКСЦЕНТРИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. эксцентрический.

**ЭКСЦЕ'СС** *м.*— эксцесс (1. тотнаксызлык, чиgennән уздырып җибәрү, чиктән ашу, үз-үзеңне тота белмәү, артык, чамасыз кылану; *чувственные эксцессы* — хис тотнаксызлыклары; 2. иҗтимагый тәртипне бозу; *предотвратить эксцессы* — иҗтимагый тәртип бозуларны булдырмау).

**ЭКЮ'** *м.* и *ср. нескл.*— экю (борынгы Франциядә алтын яки көмеш тәңкә); *золотой экю* — алтын экю.

**ЭЛАСТИ'ЧЕСКИЙ** *устар.*— к. эластичный 1.

**ЭЛАСТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. эластиклык, сыгылмалылык, сыгылучанлык, сузылучанлык; *эластичность резины* — резинаның эластиклыгы (сузылучанлыгы); 2. салмаклык, талгынлык; *эластичность движения* — хәрәкәтнең салмаклыгы.

**ЭЛАСТИ'ЧНЫЙ** — 1. эластик, сыгылмалы, сыгылучан, сузылмалы; *эластичная пружина* — сыгылмалы пружина; 2. *перен.* салмак, талгын; *эластичное движение* — салмак хәрәкәт; 3. *перен. книж. неодобр.* яраклашучан, компромисска (килешүгә) тартым, компромисска килүчән, чуар; *эластичная совесть* — чуар намус.

**ЭЛЕВА'ТОР** *м.*— элеватор (1. кирәкле механизмнар белән җиһазландырып ашлык саклау өчен эшләнгән бик зур бина; 2. *спец.* нәрсәне дә булса бер урыннан икенче урынга бушату аппараты; 3. *мед.* тешне суырып алу коралы, каргаборын).

**ЭЛЕГА'НТНОСТЬ** *ж. мн.* нет— 1. күркәмлек, купшылык, көязлек, нәфислек; *элегантность костюма* — костюмның купшылыгы; 2. (купшы, көяз) күркәм кыланыш; *она отличалась постоянной элегантностью* — ул һәрвакыт үзенең купшы кыланышы белән аерылып тора иде.

**ЭЛЕГА'НТНЫЙ** — күркәм, купшы, көяз; *элегантный костюм* — купшы костюм.

**ЭЛЕГИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *лит.* элегик, элегия...-ы; *элегическая поэзия* — элегик поэзия; *элегический жанр* — элегия жанры; 2. *перен. книж.* уйчан, моңсу, сагышлы, кайгылы; *элегическое настроение* — моңсу настроение, үз-үзеңне моңсу хис итү.

**ЭЛЕГИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— уйчанлык, моңсулык, сагышлы, кайгылы булу.

**ЭЛЕГИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. элегический 2.

**ЭЛЕ'ГИЯ** *ж. лит. муз.*— элегия (моңсу, кайгылы, сагышлы лирик шигырь яки музыкаль әсәр).

**ЭЛЕКСИ'Р** *м.*— к. эликсир.

**ЭЛЕКТРИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — 1. *физ.* электризация, электрлау, электрлану, электр белән кору; 2. *мед.* электризация, электр белән дәвалау; *сеанс электризации* — электр белән дәвалау сеансы.

**ЭЛЕКТРИЗОВА'ТЬ** *сов.* и *несов.*— 1. *физ.* электризацияләү, электрлау, электрландыру, электр белән кору; *электризовать гребешок* — таракны электрлау; 2. *мед.* электр йогынтысында тоту; электр белән дәвалау, электризацияләү; *электризовать больную руку* — авыру кулны электризацияләү, авыру кулны электр йогынтысында тоту.

**ЭЛЕКТРИЗОВА'ТЬСЯ** — 1. *сов.* и *несов. физ.* электрлану, электр белән корылу; 2. *несов. страд. физ. мед.* электрландырылу; электр йогынтысында тотылу, электр белән дәвалану.

**ЭЛЕ'КТРИК** *м. разг.*— 1. к. электротехник; 2. электрик, электр предприятиеләрендә эшләүче кеше.

**ЭЛЕКТРИ'К** *неизмен. прилаг.*— зәңгәрсу-соры, күксел-соры; *платье электрик* — зәңгәрсу-соры күлмәк.

**ЭЛЕКТРИФИКА'ТОР** *м. тех.*— электрификатор, электрификация белән шөгыльләнүче кеше, электрификация үткәрүче кеше.

**ЭЛЕКТРИФИКА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет— электрификация, электрлаштыру (1. электр энергиясен халык хуҗалыгының һәм көнкүрешнең төрле тармакларына кертү; *электрификация железных дорог* — тимер юлларны электрлаштыру; 2. нәрсәне дә булса электр белән яктыртуга күчерү, электр белән яктырта башлау, электр үткәрү; *электрификация деревни* — авылны электрлаштыру).

**ЭЛЕКТРИФИЦИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. тех.*— электрификацияләү, электрлаштыру; *электрифицировать страну* —илне электрлаштыру.

**ЭЛЕКТРИФИ'ЦИРОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов. тех.*— электрификацияләнү, электрлаштырылу.

**ЭЛЕКТРИ'ЧЕСКИЙ** —1. электр...-ы; *электрический ток* — электр тогы; *электрическая станция* — электр станциясе; 2. *зоол.* электрлы, электр заряды тудыручы; *электрические рыбы* — электрлы балыклар (электр корылмасы тудыручы органнары булган балыклар).

**ЭЛЕКТРИ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *физ.*— электр.

**ЭЛЕКТРИ'ЧКА** *ж. разг.*— электричка (1. электр тимер юлы; 2. электр тимер юлында йөрүче поезд).

**ЭЛЕКТРОАВТОМАТИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — электроавтоматизация (электр көче белән эшли торган автоматлар урнаштыру, электр көче белән эшли торган автоматлар системасын булдыру).

**ЭЛЕКТРОАВТОМА'ТИКА** *ж. мн.* нет — электроавтоматика, электр көче белән эшли торган автоматлар.

**ЭЛЕКТРОАППАРАТУ'РА** *ж. мн.* нет — электроаппаратура, электр аппаратлары.

**ЭЛЕКТРОБУ'Р** *м. тех.*— электробур, электр көче белән эшли торган бораү (скважиналар бораулауда кулланыла).

**ЭЛЕКТРОВИБРА'ТОР** *м. тех.*— электровибратор, электр көче белән эшли торган тибрәткеч.

**ЭЛЕКТРОВОДОКА'ЧКА** *ж.*— электроводокачка, электр көче белән су чыгара торган насос.

**ЭЛЕКТРОВО'З** *м. тех.*— электровоз (тимер юлда поездны, шахталарда вагонеткаларны йөртү өчен кулланыла торган электр двигателе).

**ЭЛЕКТРО'Д** *м.*— электрод (1. сыекчага яки газга тоташтырылган электр үткәргече; *положительный электрод* — унай электрод (анод); *отрицательный электрод* — тискәре электрод (катод); 2. электр чыбыгында аерым бүлемтекләрнең һәр ике очы).

**ЭЛЕКТРОДВИ'ГАТЕЛЬ** *м. тех.*— электр двигателе (электр белән хәрәкәткә килә торган двигатель).

**ЭЛЕКТРОДВИ'ЖУЩИЙ** *физ.*— электр йөртүче, электр йөртү...-ы; *электродвижущая сила* — электр йөртү көче.

**ЭЛЕКТРОДИНА'МИКА** *ж. мн.* нет, *физ.*— электродинамика (физикада хәрәкәттәге электр тогының үзлекләрен өйрәнүче бүлек).

**ЭЛЕКТРОДИНАМИ'ЧЕСКИЙ** *физ.*— электродинамик; *электродинамическое реле* — электродинамик реле.

**ЭЛЕКТРОЁМКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.*— электрсыешлык.

**ЭЛЕКТРОКА'Р** *м. тех.*— электрокар, электр арбасы.

**ЭЛЕКТРОЛЕЧЕ'БНИЦА** *ж. мед.*— электр белән дәвалау йорты.

**ЭЛЕКТРОЛЕЧЕ'БНЫЙ** *мед.*— электр белән дәвалау...-ы; *электролечебный кабинет* — электр белән дәвалау кабинеты.

**ЭЛЕКТРОЛЕЧЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет, *мед.*— электр белән дәвалау.

**ЭЛЕКТРО'ЛИЗ** *м. мн.* нет, *физ.*— электролиз (эремә хәлендәге аерым матдә аша электр тогы үткәреп, аны үзен тәшкил иткән төрле состав өлешләргә аеру).

**ЭЛЕКТРОЛИ'Т** *м. физ.*— электролит (аерым матдәнең электролиз вакытында төрле состав өлешләргә аерылырга сәләтле булган эремәсе).

**ЭЛЕКТРОЛИТИ'ЧЕСКИЙ** *физ.*— 1. электролитик, электролиз...-ы; *электролитическая ванна* — электролиз ваннасы; 2. электролитик, электролиз ярдәмендә алынган; *электролитическое железо* — электролиз ярдәмендә алынган тимер.

**ЭЛЕКТРОМАГНЕТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *физ.*— электромагнетизм (электр тогы белән тудырылган магнит күренешләре).

**ЭЛЕКТРОМАГНИ'Т** *м. физ.*— электромагнит (изоляцияләнгән тимер чыбык белән уратылган һәм шушы тимер чыбык аркылы электр тогы үткәргәндә магнитлана торган тимер яки корыч кисәге).

**ЭЛЕКТРОМАГНИ'ТНЫЙ** *физ.*— электромагнитик, электромагнетизм...-ы; *электромагнитная индукция* — электромагнитик индукция; *электромагнитные явления* — электромагнетизм күренешләре.

**ЭЛЕКТРОМЕТАЛЛУРГИ'ЧЕСКИЙ** *тех.*— электрометаллургик, электрометаллургия ...-ы; *электрометаллургический завод* — электрометаллургия заводы.

**ЭЛЕКТРОМЕТАЛЛУ'РГИЯ** *ж. мн.* нет, *тех.*— электрометаллургия (техниканың төрле рудалардан электр тогы ярдәмендә металл яки эретмә чыгаруга караган өлкәсе).

**ЭЛЕКТРО'МЕТР** *м. физ.*— электрометр (электр көчәнешен үлчәү приборы).

**ЭЛЕКТРОМЕХА'НИК** *м.*— электромеханик, электромеханика белгече.

**ЭЛЕКТРОМЕХА'НИКА** *ж. мн.* нет — электромеханика (электротехниканың электр двигательләре, машиналары эшләүгә

һәм аларны эксплуатацияләүгә караган тармагы).

**ЭЛЕКТРОМЕХАНИ'ЧЕСКИЙ** *тех.*— электромеханик, электромеханика..-ы; *электромеханический завод* — электромеханика заводы.

**ЭЛЕКТРОМОНТА'Ж** *м. мн.* нет, *тех.*— электромонтаж (1. электр приборларын, җиһазларын җыю, кору, урнаштыру; 2. электр үткәрү).

**ЭЛЕКТРОМОНТЁР** *м.*— электромонтёр (электромонтаж белән шөгыльләнүче белгеч).

**ЭЛЕКТРОМОТО'Р** *м. тех.*— электромотор (электр белән эшләүче мотор).

**ЭЛЕКТРО'Н** *м.*— электрон (1. *физ.* атом составындагы тискәре электр зарядлы кисәкчә; 2. *только ед. тех.*— очу аппаратлары ясауда кулланыла торган җиңел магний эретмәсе).

**ЭЛЕКТРОНАСО'С** *м.*— электронасос, электр насосы.

**ЭЛЕКТРО'НИКА** *ж. мн.* нет, *физ.*— электроника (электротехниканың газлардагы һәм һавасыз бушлыклардагы электр күренешләрен һәм ул күренешләрдән файдалану ысулларын өйрәнә торган бүлеге).

**ЭЛЕКТРО'ННЫЙ** — электрон...-ы; *электронный микроскоп* — электрон микроскобы.

**ЭЛЕКТРООБОРУ'ДОВАНИЕ** *ср. мн.* нет — электр җиһазлары, электр әсбаплары.

**ЭЛЕКТРОПА'ХОТА** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— электр сабаны белән (җир) сөрү.

**ЭЛЕКТРОПЕРЕДА'ЧА** *ж. тех.*— 1. электр энергиясен берәр ераклыкка тапшыру; 2. электр энергиясен тапшыру җайланмалары, корылмалары.

**ЭЛЕКТРОПЕ'ЧЬ** *ж.*— электр миче.

**ЭЛЕКТРОПИЛА'** *ж. тех.*— электр пычкысы, электр көче белән эшли торган пычкы.

**ЭЛЕКТРОПИ'ЛКА** *ж. мн.* нет — электр пычкысы белән яру (кисү).

**ЭЛЕКТРОПЛА'ВКА** *ж. мн.* нет — электр белән металл эретү.

**ЭЛЕКТРОПЛУ'Г** *м. с.-х.*— электр сабаны (электр белән эшли торган сабан).

**ЭЛЕКТРОПРОВО'ДНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *физ.*— электр үткәрүчелек, электр үткәрү сәләте.

**ЭЛЕКТРОПРОВО'ДНЫЙ** *физ.*— электр үткәрүче, электр үткәрүгә сәләтле; *электропроводные металлы* — электр үткәрүче металлар.

**ЭЛЕКТРОПРОМЫ'ШЛЕННОСТЬ** *ж. мн.* нет — электр промышленносте; *министерство электропромышленности* — электр промышленносте министрлыгы.

**ЭЛЕКТРОРЕ'ЗКА** *ж. мн.* нет, *тех.*— электр тогы ярдәмендә кисү, электр тогы белән кисү (металларны).

**ЭЛЕКТРОСВА'РКА** *ж. мн.* нет, *тех.*— электр тогы белән эретеп ябыштыру, электр тогы ярдәмендә эретеп ялгау (металларны).

**ЭЛЕКТРОСВА'РЩИК** *м. тех.*— электросварщик (металларны электр тогы белән эретеп ябыштыру остасы).

**ЭЛЕКТРОСИЛОВО'Й** *тех.*— электр энергиясе белән эшли торган.

**ЭЛЕКТРОСКО'П** *м. физ.*— электроскоп (электр заряды барлыгын билгеләү приборы).

**ЭЛЕКТРОСНАБЖЕ'НИЕ** *ср. мн.* нет — электр энергиясе белән тәэмин итү.

**ЭЛЕКТРОСТА'ЛЬ** *ж. мн.* нет, *тех.*— электр корычы (электр мичендә коелган югары сортлы корыч).

**ЭЛЕКТРОСТА'НЦИЯ** *ж.*— электростанция, электр станциясе.

**ЭЛЕКТРОСТА'ТИКА** *ж. мн.* нет — электростатика (физиканың хәрәкәттә булмаган электр зарядлары үзенчәлекләрен өйрәнү бүлеге).

**ЭЛЕКТРОСТАТИ'ЧЕСКИЙ** *физ.*— электростатик, электростатика...-ы; *электростатическая индукция* — электростатика индукциясе.

**ЭЛЕКТРОТЕРАПЕВТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.*— электротерапевтик, электротерапия...-ы; *электротерапевтический кабинет* — электротерапия кабинеты.

**ЭЛЕКТРОТЕРАПИ'Я** *ж. мн.* нет, *мед.*— электротерапия, электр белән дәвалау.

**ЭЛЕКТРОТЕ'ХНИК** *м.*— электротехник (1. электротехника белгече; 2. электротехник уку йортында укучы).

**ЭЛЕКТРОТЕ'ХНИКА** *ж. мн.* нет — электротехника (1. электрны практик максатлардан чыгып куллану турындагы фән; 2. *тех.* промышленностьның электр энергиясен практик куллану буенча җиһазлар җитештерә торган тармагы).

**ЭЛЕКТРОТЕХНИ'ЧЕСКИЙ** — электротехник, электротехника...-ы; *электротехнический институт* — электротехника институты.

**ЭЛЕКТРОФО'Р** *м. физ.*— электрофор (ышку юлы белән электр зарядлары тудыручы прибор).

**ЭЛЕКТРОХИМИ'ЧЕСКИЙ** *хим. физ.*— электрохимик, электрохимия...-ы; *электрохимические приборы* — электрохимия приборлары.

**ЭЛЕКТРОХИ'МИЯ** *ж. мн.* нет, *хим. физ.*— электрохимия (физик химиянең электр тогы ярдәмендә барлыкка китерелгән химик процессларны һәм химик процесслар нәтиҗәсендә тудырылган электр күренешләрен өйрәнүче тармагы).

**ЭЛЕМЕ'НТ** *м.*— 1. элемент, өлеш, кисәк; *важнейшие элементы драматического произведения* — драматик әсәрнең иң мөһим элементлары; 2. *только мн.* башлангыч мәгълүмат, төп кагыйдәләр, башлангыч белем; *элементы математики* — математиканың төп кагыйдәләре; 3. *разг.* кеше, шәхес; *ненадёжный элемент* — ышанычсыз кеше; 4. *простореч.* контрреволюционер, явыз кеше, элемент, мәкерле кеше; 5. *мат.* дифференциал, чиксез кечкенә зурлык;

6. элемент (а. *хим.* гадәттәге химик юллар белән тагы да гадирәк состав өлешләргә бүленә алмый торган химик матдә; *периодическая система элементов* — элементларның периодик системасы; б. *книж.* катлаулы бер әйбернең характерлы үзенчәлеген яки төп нигезен тәшкил иткән кисәк, өлеш; *элементы драматизма в рассказе* — хикәядә драматизм элементлары; в. *физ.* электр тогы тудыручы прибор; *сухие элементы* — коры элементлар).

**ЭЛЕМЕНТА'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— элементарлык (1. гадилек, үзеннән-үзе аңлашылып торганлык; 2. җиңелчәлек, чикләнгәнлек, өстән-өстән генә булу).

**ЭЛЕМЕНТА'РНЫЙ** — 1. *с вц. науч.* элементар; *элементарный состав топлива* — ягулыкның элементар составы; *элементарный анализ* — элементар анализ; 2. элементар, башлангыч, төп нигезләрне эченә алган, төп; *элементарная математика* — элементар математика; 3. *перен. книж.* гади, ачык аңлаешлы; *элементарный пример* — гади мисал; 4. төп, нигез, иң мөһим; *элементарное условие* — төп шарт; 5. җиңелчә, өстән генә, чикләнгән; *элементарный взгляд на вещи* — аерым мәсьәләләргә җиңелчә караш.

**ЭЛЕРО'Н** *м. ав.*— элерон (самолёт канатларының артына шарнир ярдәмендә беркетелгән һәм самолётны билгеле юнәлешкә бору өчен эшләнгән җайланма).

**ЭЛЕФАНТИА'З, ЭЛЕФАНТИА'ЗИС** *м. мн.* нет, *мед.*— элефантиазис, фил авыруы (тиренең һәм тире асты күзәнәкләренең гадәттән тыш калынаюы).

**ЭЛИЗЕ'Й, ЭЛИ'ЗИЙ** *м. мн.* нет — к. элизиум.

**ЭЛИЗИ'ЙСКИЙ** *книж. поэт. устар.*— элизий ...-ы, оҗмах...-ы, җәннәт...-ы; *элизийские поля* — җәннәт кырлары.

**ЭЛИ ЗИУМ** *м. мн.* нет — 1. Элизиум (антик мифологиядә үлгән кешеләрнең җаннары яши торган урын; 2. *перен. книж. поэт. устар.* оҗмах, җәннәт; *душа моя — Элизиум теней* (Тютчев)— минем җаным— күләгәләр җәннәте.

**ЭЛИ'ЗИЯ** *ж. лит. лингв.*— элизия (сүз ахырында килгән сузык авазның икенче сүзне башлаган сузык аваз алдында төшеп калуы, мәсәлән, „бара алмыйм" урынына „баралмыйм" дип сөйләү).

**ЭЛИКСИ'Р** *м.* — 1. *мед. апт.* эликсир (үсемлек матдәләрен спиртта, кислотада һ. б. эретеп ясалган сыекча, дару); 2. *книж. устар.* эчемлек, шәраб; *любовный эликсир* — мәхәббәт шәрабы.

**ЭЛИМИНА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *книж.*— к. элиминировать.

**ЭЛИМИНИ'РОВАТЬ** *несов. книж.* — юк итү, юкка чыгару, бетерү, чыгарып ташлау; *элиминировать препятствия* — каршылыкларны юкка чыгару (юк итү, бетерү).

**ЭЛИМИНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. книж. страд.* — юк ителү, юкка чыгарылу, чыгарып ташланылу.

**ЭЛИ ТА** *ж. мн.* нет — элита (1. *книж.* сайланган кешеләр даирәсе; 2. *собир. с.-х.* аерым үсемлекләрнең яки хайваннарның сайлап алынган иң яхшы төрләре, токымнары; 3. *с. х.* үсемлекләрне яки хайваннарны сайлап алу).

**ЭЛИ'ТНЫЙ** *с.-х.*—элита...-ы, сайлап алынган; *элитные животные* — элита хайваннары, сайлап алынган хайваннар.

**ЭЛИ'ТРЫ** *мн. зоол.*— к. надкрылья.

**Э'ЛЛИН** *м. книж.*— эллин, борынгы грек.

**Э'ЛЛИНГ** *м. мор.*— эллинг (1. судно корпусы төзелә торган авыш фундамент, җайланма; 2. *ав.* дирижабльләр һәм аэростатлар кую өчен ясалган бина).

**ЭЛЛИНИ'ЗМ** *м. мн.* нет — эллинизм (1. к. грецизм; 2. *истор.* борынгы греклар (эллиннар) культурасы, аеруча аның Александр Македонский яулап алуларыннан соң Көнчыгышта таралган чоры).

**ЭЛЛИНИ'СТ** *м.*— эллинист (1. *филол.* грек филологиясе белгече; 2. *книж.* борынгы Греция белән кызыксынучы кеше; борынгы грек культурасын яратучы кеше).

**ЭЛЛИНИСТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— 1. эллинизм ...-ы, борынгы грек культурасы ...-ы; эллинистик; *эллинистический период* — эллинизм чоры; 2. борынгы греклар (эллиннар) ...-ы; *эллинистическая культура*— борынгы греклар культурасы.

**Э ЛЛИНКА** *ж. книж.*— эллинка, борынгы грек хатын-кызы.

**Э'ЛЛИНСКИЙ** *книж.*— эллин...-ы, борынгы грек...-ы; *эллинская речь* — эллин сөйләше, борынгы грек сөйләше.

**Э'ЛЛИПС, Э'ЛЛИПСИС** *м.*— эллипс (1. *мат.* конусны яки цилиндрны яссылык белән кисү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган һәм формасы белән йомыркага охшаган йомык кәкре сызык; 2. *грам. лит.* җөмләнең үзеннән-үзе билгеле булган берәр кисәген төшереп калдыру).

**ЭЛЛИПСО'ИД** *м. мат.*— эллипсоид (эллипсның үз күчәрләренең берсе тирәсендә әйләнүеннән барлыкка килә торган, йомыркага, шарга охшаган геометрик җисем).

**ЭЛЛИПТИ ЧЕСКИЙ** *мат. грам. лит.*— эллиптик; *эллиптическая форма тела* — җисемнең эллиптик формасы; *эллиптическое предложение* — эллиптик җөмлә (берәр кисәге төшеп калган җөмлә).

**ЭЛЬ** *м.*— эль (куе инглиз сырасы).

**ЭЛЬДОРА'ДО** *ср. нескл. книж.*— эльдорадо (хыялый байлыклар һәм могҗизалар иле).

**ЭМА'ЛЕВЫЙ** — эмаль ..., эмальдән ясалган, эмальдән эшләнгән; *эмалевый жетон* — эмаль жетон. ◇ **Эмалевые краски** *спец.*— эмаль буяулар (кипкәннән соң әйберләр өстендә эмальгә охшаган шома, ялтыравык каты катлау калдыра торган буяулар).

**ЭМАЛИРО'ВАННЫЙ** — эмальләнгән, эмаль белән капланган, эмаль белән буялган; *эмалированная посуда* — эмаль белән буялган савыт-саба.

**ЭМАЛИРОВА'ТЬ** *несов.* — эмальләү, эмаль белән каплау, эмаль белән буяу.

**ЭМАЛИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд.*—

**Э'НДШПИЛЬ** *м. шахм.* — эндшпиль (шахмат уенының тәгәлләнү стадиясе).

**ЭНЕРВА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— энервация (нервларның какшавы, арыгаюы, йончуы).

**ЭНЕРГЕТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *филос.*— энергетизм (эмпириокритицизмга якын реакцион идеалистик өйрәтмә).

**ЭНЕРГЕ'ТИК** *м.*— энергетик (1. энергетизм тарафдары; 2. энергетика белгече).

**ЭНЕРГЕ'ТИКА** *ж. мн.* нет — энергетика (1. *филос.* к. энергетизм; 2. физиканың энергия үзлекләрен өйрәнү бүлеге; 3. техниканың төрле энергияләрне куллану һәм файдалану юлларын өйрәнүче бер тармагы; 4. төрле энергияләрне файдаланучы һәм эшләп чыгаручы техника).

**ЭНЕРГЕТИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *филос.* энергетик, энергетикларга хас, энергетиклар ...-ы, энергетикларча ...; *энергетический взгляд*— энергетиклар карашы; 2. *физ. тех.* энергетик, энергетика ...-ы; *энергетическое хозяйство* — энергетика хуҗалыгы.

**ЭНЕРГИ'ЧЕСКИЙ** *книж. устар.* — к. энергичный.

**ЭНЕРГИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет — энергиялелек, көчлелек, гайрәтлелек, эшчәнлек, тырышлык.

**ЭНЕРГИ'ЧНЫЙ** — 1. энергияле, көчле, гайрәтле, эшчән, тырыш; *энергичный человек* — тырыш кеше; 2. бик нык тәэсир ясый торган, көчле; *энергичное лекарство* — көчле дару.

**ЭНЕ'РГИЯ** *ж. мн.* нет — 1. *физ. тех.* энергия, куәт; *учение об энергии* — энергия турында тәгълимат; *тепловая энергия* — җылылык энергиясе; 2. энергия, көч, гайрәт, тырышлык; *тратить много энергии* — бик күп көч түгү, бик күп энергия сарыф итү.

**ЭНИГМАТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— серле, аңлашылмый торган, гаҗәп, сәер; *энигматическая внешность* — серле кыяфәт.

**ЭНИГМАТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— серлелек, аңлашылмый торган булу, гаҗәплек, сәерлек.

**ЭНИГМАТИ'ЧНЫЙ** *книж.*— к. энигматический.

**ЭНКЛИ'ТИКА** *ж. лингв.*— энклитика (үзеннән алдагы сүзгә ялганып басымын югалткан тагылма сүз яки кисәкчә).

**ЭНКЛИТИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.* — энклитик; *энклитическое слово* — энклитик сүз.

**Э'ННЫЙ** — 1. *мат.* һәрбер, ниндидер бер; *энное число* — ниндидер бер сан; 2. *перен. разг. шутл.* бик күп; *говорить одно и то же в энное количество раз* — бер үк нәрсәне бик күп мәртәбә сөйләү.

**ЭНТЕРИ'Т** *м. мед.*— энтерит (нечкә эчәкләрнең ялкынсынуы).

**ЭНТОМО'ЛОГ** *м.*— энтомолог, энтомология белгече.

**ЭНТОМОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** — энтомологик, энтомологиягә хас.

**ЭНТОМОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — энтомология (зоологиянең бөҗәкләрне өйрәнүгә караган бүлеге).

**ЭНТУЗИА'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— энтузиазм, зур дәрт, гайрәт, рух күтәренкелеге; *трудиться с энтузиазмом* — зур дәрт белән эшләү, энтузиазм белән эшләү.

**ЭНТУЗИА'СТ** *м.*, **ЭНТУЗИА'СТКА** *ж. книж.*— энтузиаст, дәртле кеше, (нәрсәне дә булса) ялкынланып башкаручы кеше, (нәрсәне дә булса) күтәренке рух белән башкаручы кеше, (нәрсәне дә булса) бирелеп башкаручы кеше, яратып эшләүче кеше, (нәрсә белән булса) яратып шөгыльләнүче кеше; *энтузиаст лыжного спорта* — чаңгы спорты энтузиасты, чаңгы спорты белән яратып шөгыльләнүче кеше; *энтузиаст искусства* — сәнгать энтузиасты, сәнгатькә караган эшләрне ялкынланып башкаручы кеше.

**ЭНЦЕФАЛИ'Т** *м. мед.*— энцефалит (баш миенең ялкынсынуы).

**ЭНЦИКЛОПЕДИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*— энциклопедизм (фәннең, белемнең бик күп тармаклары белән таныш булу, һәр яктан мәгълүматлы булу).

**ЭНЦИКЛОПЕДИ'СТ** *м.*— энциклопедист (1. *книж.* фәннең, белемнең бик күп тармаклары белән таныш кеше, һәр яктан мәгълүматлы кеше; 2. *истор.* Франциядә XVIII йөз ахырында чыгарылган „Энциклопедия" тирәсенә тупланган алдынгы фикер ияләренең бер вәкиле).

**ЭНЦИКЛОПЕДИ'СТКА** *ж. книж.*— к. энциклопедист 1.

**ЭНЦИКЛОПЕДИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— 1. энциклопедик, энциклопедия ...-ы; *энциклопедический словарь* — энциклопедик сүзлек; 2. *перен.* бөтен яктан, һәрьяклап; *энциклопедически образованный человек* — һәрьяклап белемле кеше.

**ЭНЦИКЛОПЕ'ДИЯ** *ж.* — энциклопедия (1. белемнең барлык яки аерым тармакларына карата сүзлек формасында төзелгән белешмә, кулланма; 2. берәр фәннең төрле тармаклары буенча системага салынган күзәтү). ◇ **Ходячая энциклопедия** *шутл.*— белем капчыгы, аяклы энциклопедия (теләсә нинди мәсьәлә буенча белешмә алырга мөмкин булган кеше турында әйтелә).

**ЭОЗО'ЙСКИЙ** *геол.*— эозой...-ы (геологик эра турында); *эозойская эра* — эозой эрасы.

**ЭОЛИ'Т** *м. археол.*— эолит (1. *только ед.* таш чорының иң борынгы стадиясе; 2. шушы чорга караган бик примитив таш корал).

**ЭОЛИ'ТОВЫЙ** *археол.*—эолит ...-ы, эолит стадиясенә караган; *эолитовое орудие* — эолит коралы, эолит стадиясенә караган корал.

**ЭПАТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*— ис китәрү, шак катыру, таң калдыру, гаҗәпкә калдыру (җәнҗал, шау-шу куптарып).

**ЭПАТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*— ис китәрелү, шак катырылу, таң калдырылу, гаҗәпкә калдырылу (җәнҗал, шау-шу куптарылып).

**ЭПЕНТЕ'ЗА** *ж. лингв.* — эпентеза (сүз эченә артык аваз кушу; мәсәлән, „универ-

ситет" урынына „универститет" дип әйткәндә „т" авазы).

**ЭПЕНТЕТИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.*— эпентетик, сүз эченә кушылган; *эпентетический звук* — эпентетик аваз.

**ЭПИГЛО'ТТИС** *м. анат.*— к. надгортанник.

**ЭПИГО'Н** *м. книж.*— эпигон, тәкълитче (нинди дә булса әдәби, фәнни яки политик юнәлешкә сукырларча ияреп, үз элгәрләренең искергән, вакыты узган идеяләрен, методларын кабатлаучы кеше).

**ЭПИГО'НСКИЙ** *книж.*— эпигон ..., иярүдән гыйбарәт, тәкълит итүдән гыйбарәт, төссез, иҗат үзенчәлеге булмаган; *эпигонское искусство* — эпигон сәнгать, иҗат үзенчәлеге булмаган сәнгать.

**ЭПИГО'НСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— эпигонлык, иярү, тәкълит итү, төссезлек, иҗат үзенчәлеге булмау.

**ЭПИГРА'ММА** *ж. книж.* — эпиграмма (1. *истор. лит.* борынгы грекларда кабер ташларындагы, иҗтимагый биналардагы һ. б. язу; 2. *лит.* антик поэзиядә гекзаметр һәм пентаметр белән язылган, соңыннан исә сатирик эчтәлек алган кечкенә күләмле шигырь; 3. *лит.* хәзерге поэзиядә сатирик эчтәлекле кыска гына шигырь).

**ЭПИГРАММАТИ'СТ** *м. лит.*— эпиграммалар язучы.

**ЭПИГРАММАТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*—1. эпиграмматик, эпиграмма ...-ы; эпиграммага хас; *эпиграмматическая литература* — эпиграмматик әдәбият; *эпиграмматический стиль* — эпиграмма стиле, эпиграммага хас стиль; 2. *перен.* зәһәр, әче, чәнчүле; *эпиграмматический выпад против кого-нибудь* — берәр кешегә каршы зәһәр чыгыш.

**ЭПИ'ГРАФ** *м.*— эпиграф (1. борынгы грекларда кабер ташларындагы язу; 2. әсәрнең яки аның берәр бүлеге кисәгенең башында бирелгән һәм шушы әсәрнең, бүлекнең, кисәкнең төп идеясен яктырткан кыскача текст, гадәттә аерым цитата, мәкаль, әйтем, хикмәтле сүз).

**ЭПИГРА'ФИКА** *ж. археол. филол.* — эпиграфика (ташъязмалар, өсъязмалар турындагы фән).

**ЭПИГРАФИ'СТ** *м.*— эпиграфист, эпиграфика белгече.

**ЭПИГРАФИ'ЧЕСКИЙ** I. *лит.*— эпиграфик, эпиграф ...-ы, эпиграф өчен ...; *эпиграфический текст* — эпиграф тексты.

**ЭПИГРАФИ'ЧЕСКИЙ** II *археол. филол.*— эпиграфик, эпиграфика ...-ы, эпиграфикага караган; *эпиграфические материалы для изучения античной истории* — антик тарихны өйрәнү өчен эпиграфика материаллары.

**ЭПИДЕМИО'ЛОГ** *м. спец.* — эпидемиолог, эпидемиология белгече.

**ЭПИДЕМИОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.*— эпидемиологик, эпидемиология ...-ы, эпидемиологиягә караган; *эпидемиологический институт* — эпидемиология институты.

**ЭПИДЕМИОЛО'ГИЯ** *ж. мед.*— эпидемиология (киң таралган йогышлы авырулар турындагы фән, эпидемияләр турындагы фән).

**ЭПИДЕМИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — эпидемик, эпидемия ...-ы, кизү ...-ы, киң таралган; *эпидемическая болезнь* — кизү чире.

**ЭПИДЕ'МИЯ** *ж.*— 1. эпидемия, кизү (киң таралган йогышлы чир); *эпидемия тифа* — тиф эпидемиясе, тиф кизүе.

**ЭПИДЕ'РМА** *ж.*, **ЭПИДЕ'РМИС** *м. мн.* нет — эпидерма (1. *анат.* тиренең өске катлавы; 2. *бот.* кайбер үсемлек кабыгының өске катлавы).

**ЭПИЗО'Д** *м.*— 1. эпизод (а. *лит. истор.* борынгы грек драмаларында пәрдәнең хор чыгышлары арасындагы күренеше; б. әдәби әсәрнең теге яки бу күләмдә тәмамланган яки үз алдына әһәмияте булган кисәге; в. хәл, вакыйга, хадисә).

**ЭПИЗОДИ'ЧЕСКИЙ, ЭПИЗОДИ'ЧНЫЙ** *книж.*— очраклы, көтелмәгән, көтмәгәндә булган; *эпизодическая встреча* — көтелмәгән очрашу.

**ЭПИЗООТИ'ЧЕСКИЙ** *ветер.*— эпизоотик, эпизоотия ...-ы; эпизоотиягә хас; *эпизоотическое явление* — эпизоотия күренеше.

**ЭПИЗОО'ТИЯ** *ж.ветер.*— эпизоотия (терлекләр арасында киң таралган йогышлы чир, үләт).

**Э'ПИК** *м. лит.*— эпик (эпик әсәрләр авторы).

**Э'ПИКА** *ж. мн.* нет, *лит.*— эпика (эпик әсәрләр).

**ЭПИКА'РД, ЭПИКА'РДИЙ** *м. анат.*— эпикард (йөрәкне тышкы яктан каплап алган пәрдә, сүрү).

**ЭПИКАРДИ'Т** *м. мн.* нет, *мед.*— эпикардит, эпикардның ялкынсынуы (йөрәкнең тышкы пәрдәсенең ялкынсынуы).

**ЭПИКУРЕ'ЕЦ** *м. книж.*— 1. эпикуреец эпикуреизм тарафдары; 2. хис ләззәтләренә бирелергә яратучы кеше, рәхәт(кәеф-сафалы) тормышта яшәргә яратучы кеше.

**ЭПИКУРЕИ'ЗМ** *м. мн.* нет — эпикуреизм (1. *филос.* борынгы грек философы Эпикурның дингә каршы юнәлтелгән фәлсәфи тәгълиматы; 2. *книж* шушы тәгълиматны берьяклы аңлату нәтиҗәсендә килеп чыккан һәм кеше тормышының мәгънәсе хис инстинктларын канәгатьләндерүдән, рәхәт яшәүдән гыйбарәт дигән караш; 3. хис ләззәтләренә бирелергә ярату, кәеф-сафалы тормышта яшәргә ярату).

**ЭПИКУРЕ'ЙСКИЙ** *филос. книж.*—1. эпикуреизм ...-ы; *эпикурейская философия* — эпикуреизм фәлсәфәсе; 2. эпикуреецларга хас, эпикуреецларча ...; *эпикурейская жизнерадостность* — эпикуреецларча шат күңеллелек.

**ЭПИКУРЕ'ЙСТВО** *ср. мн. нет, книж.* — к. эпикуреизм 3.

**ЭПИЛЕ'ПСИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*— эпилепсия, өянәк, зыяндаш авыруы, үз чире, үз чире тоту.

**ЭПИЛЕ'ПТИК** *м. мед.* — эпилептик, өянәкле кеше, өянәк авырулы кеше, зыяндаш авырулы кеше, үз чирле кеше, үз чире тотучан кеше.

**ЭПИЛЕПТИ'ЧЕСКИЙ** *мед.* — эпилептик.

**ЭПИЛО'Г** *м.* — 1. *лит.* эпилог, соңгы сүз (әдәби әсәрдә геройларның соңгы язмышлары белән таныштыручы йомгаклау өлеше); 2. *перен. книж.* йомгак, чишелеш; *удачный эпилог* — уңышлы йомгак.

**ЭПИСКО'П** *м. физ.* — эпископ (үтә күренми торган әйберләрне, рәсемнәрне экранда күрсәтү приборы).

**ЭПИ'СТОЛА** *ж. лит. устар.* — эпистола, хат формасында язылган әдәби әсәр.

**ЭПИСТОЛЯ'РНЫЙ** *лит.* — эпистоляр, эпистола ...-ы, хат ...-ы, хат формасындагы; *эпистолярный жанр* — эпистола жанры; *эпистолярный стиль* — хат стиле.

**ЭПИТАЛА'МА** *ж.* — эпиталама (1. *истор.* борынгы грекларда һәм римлыларда яңа өйләнешкән кешеләрне котлау җыры; 2. *лит.* өйләнешү, кавышу хөрмәтенә язылган шигырь).

**ЭПИТА'ФИЯ** *ж. книж.* — эпитафия (кабер ташларындагы язма).

**ЭПИТЕ'ЛИЙ** *м. мн.* нет, *анат.* — эпителий (хайван тәненең өстен каплап торучы тукыма).

**ЭПИ'ТЕТ** *м.* — эпитет (нәрсәнең яки кемнең дә булса сыйфатын билгеләп әйтелгән сүз).

**ЭПИЦЕ'НТР** *м. геол.* — эпицентр (җирнең зилзилә үзәге турындагы өске катлавы).

**ЭПИ'ЧЕСКИЙ** — 1. *лит.* эпик, эпос ...-ы; *эпический жанр* — эпик жанр, эпос жанры; 2. *перен. книж.* тантаналы-тыныч, тантаналы, күтәренке-тыныч, күтәренке; *говорить эпическим тоном* — тантаналы-тыныч тавыш белән сөйләү.

**ЭПОЛЕ'ТЫ** — к. погон 2.

**ЭПОПЕ'Я** *ж.* — эпопея (1. *лит. книж.* зур тарихи вакыйгаларны сурәтләгән эпик әсәр; 2. *перен. книж.* мөһим, зур вакыйгалар, нәрсәнең дә булса катлаулы һәм әһәмиятле тарихы).

**Э'ПОС** *м. мн.* нет, *лит.* — эпос (1. хикәяләү формасында язылган әсәрләр; 2. гомуми тема, милли үзенчәлек, хронология белән үзара тыгыз бәйләнгән шушы төрдәге әсәрләр).

**ЭПО'ХА** *ж.* — эпоха, чор, дәвер, вакыт, заман.

**ЭПОХА'ЛЬНЫЙ** *нов. книж.* — эпохаль, бөтен бер эпоха тәшкил итә торган, бөтен бер чор тәшкил итә торган, бөтен бер дәвер тәшкил итә торган; *эпохальные события* — бөтен бер дәвер тәшкил итә торган вакыйгалар.

**Э'РА** *ж.* — эра (1. *книж.* еллар исәбе башланып киткән вакыт яки вакыйга); 2. *книж.* билгеле бер системада еллар исәбе; 3. *только ед. книж.* үсешнең яңа бер чорын ачучы, билгеле бер эпоха ачучы әһәмиятле вакыйга; 4. *геол.* җир тарихындагы бүленештә иң озын чор).

**ЭРГОГРА'Ф** *м. спец.* — эргограф (мускулларның эшен график рәвештә язып баручы прибор).

**ЭРГОТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *мед.* — эрготизм, көзән җыеру, тартышу (икмәккә эләккән арыш анасы белән агуланудан килеп чыга торган авыру).

**ЭРЕ'КЦИЯ** *ж. мн.* нет, *физиол.* — эрекция, кабару, киерелү (көчле кан агымы һәм веналарның тыгызлануы аркасында кайбер әгъзаларның, гадәттә җенес әгъзаларының кабаруы).

**ЭРЕТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *мед.* — эретизм гадәттән тыш тәэсиргә бирелүчәнлек, гадәттән тыш кызып китүчәнлек.

**ЭРИ'СТИКА** *ж. мн.* нет, *книж.* — эристика, бәхәсләшү сәнгате, моназара кылу сәнгате.

**ЭРИТРОЦИ'ТЫ** *м. физиол.* — эритроцитлар, кызыл кан шарчыклары.

**ЭРОДИ'РОВАТЬ** *несов. геол.* — эрозиягә дучар итү, эрозия эшләү, җимерү.

**ЭРОДИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд.* — эрозиягә дучар ителү, эрозияләнү, җимерелү.

**ЭРОЗИ'ВНЫЙ** *геол. мед.* — эрозив, эрозия...-ы; *эрозивные явления* — эрозия күренешләре.

**ЭРО'ЗИЯ** *ж. мн.* нет — эрозия (1. *геол.* җир өстенең боз, агым сулар һ. б. тәэсире белән юылуы, ашалуы; 2. *мед.* тәндәге лайлалы сүрү өслегенең бетчәләнүе; 3. берәр нәрсәнең электр көче һәм атмосфера күренешләре тәэсире белән җимерелүе, таркалуы).

**Э'РОС** *м. мн.* нет, *книж.* — эрос, дәрт дәртле (кайнар) мәхәббәт.

**ЭРОТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.* — эротизм, гадәттән тыш җенси хискә бирелүчәнлек.

**ЭРО'ТИКА** *ж. мн.* нет — эротика (1. *книж.* җенси хискә бирелүчәнлек; 2. *лит.* гыйшык-мәхәббәт поэзиясе).

**ЭРОТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.* — 1. эротик, эротика...-ы, гыйшык-мәхәббәт...-ы; *эротическая поэзия* — гыйшык-мәхәббәт поэзиясе; 2. хискә бирелүчән; *эротическая натура* — хискә бирелүчән характер.

**ЭРОТИ'ЧНЫЙ** *книж.* — к. эротический 2.

**ЭРОТОМА'Н** *м.*, **ЭРОТОМА'НКА** *ж. мед. книж.* — эротоман (эротомания белән авырый торган кеше).

**ЭРОТОМА'НИЯ** *ж. мн.* нет — эротомания (1. *мед.* авыру дәрәҗәсенә җиткән җенси дәртлелек; 2. *книж.* к. эротизм).

**ЭРУДИ'Т** *м. книж.* — эрудит (фәннең берәр өлкәсендә тирән белемле кеше, укымышлы кеше).

**ЭРУДИ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — эрудиция (фәннең берәр өлкәсендә тирән белемлелек, укымышлылык).

**ЭРЦГЕ'РЦОГ** *м. истор.* — эрцгерцог (элекке Австрия императоры фамилиясе членнарының титулы).

**ЭСДЕ'К** *м. полит.* — эсдек (социал-демократ).

**ЭСДЕ'КОВСКИЙ** *полит.* — эсдек...-ы, эсдеклар...-ы; эсдекларча..., эсдекларга хас; *эсдековский взгляд* — эсдекларча караш (социал-демократларча караш).

**ЭСЕ'Р** *м.*, **ЭСЕ'РКА** *ж. полит.* — эсер (социалист-революционер; марксизмга дошман булган һәм Октябрьдан соң советлар властена каршы көрәшкән контрреволюцион партия члены).

**ЭСЕ'РОВСКИЙ** *полит.*—эсер...-ы, эсерлар...-ы; эсерларча..., эсерларга хас; *эсеровский взгляд*—эсерларча караш (социалист-революционерларча караш).

**ЭСКА'ДРА** *ж. воен. мор.*—эскадра (хәрби дингез яки һава флотында зур берләшмә); *эскадра крейсеров*—крейсерлар эскадрасы.

**ЭСКА'ДРЕННЫЙ** *воен. мор.* — эскадра...-ы, эскадра составындагы; *эскадренный миноносец*—эскадра миноносецы.

**ЭСКАДРИ'ЛЬЯ** *ав. воен.*—эскадрилья (хәрби авиациядә самолётларның берничә звеносыннан тора торган берләшмә).

**ЭСКАДРО'Н** *м. воен.*— эскадрон (атлы гаскәрнең җәяүле гаскәрдәге ротага туры килә торган бүлекчәсе).

**ЭСКАДРО'ННЫЙ** *воен.*—**1.** эскадрон...-ы; *эскадронный командир* — эскадрон командиры; **2.** *в знач. сущ. разг.* эскадрон командиры.

**ЭСКАЛА'ТОР** *м.*— эскалатор (туктаусыз хәрәкәт итүче баскыч, мәсәлән, метрода).

**ЭСКАЛА'ТОРНЫЙ** — **1.** эскалатор...-ы; *эскалаторные ступеньки* — эскалатор баскычлары; **2.** *спец.* эскалатор...-ы, (нәрсәне дә булса) арттыра баруга хокук бирә торган; *эскалаторная статья договора* — килешүнең эскалатор статьясы, килешүнең нәрсәне дә булса арттыра баруга хокук бирә торган статьясы.

**ЭСКАМОТА'Ж** *м. мн.* нет, *книж.*— к. эскамотировать.

**ЭСКАМОТИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. книж.*—(алдау нияте белән) сиздерми яшерү, сизелмәслек итеп алмаштыру, оста итеп яшерү, оста итеп алмаштыру, оста итеп урлау, оста итеп алдау.

**ЭСКАМОТИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. книж.*—(алдау нияте белән) сиздерми яшерелү, сизелмәслек итеп алмаштырылу, оста итеп яшерелү, оста итеп алмаштырылу, оста итеп урлану, оста итеп алдану.

**ЭСКА'РП** *воен.*— эскарп (хәрби нигытма тышындагы чокырның бруствергa барып тоташкан арткы сөзәк урыны).

**ЭСКВА'ИР** *м.*—к. сквайр.

**ЭСКИ'З** *м. живоп. книж.*—эскиз (картинаның, рәсемнең, әсәрнең, текстның һ. б. башлангыч, өстән-өстән генә эшләнгән яки язылган варианты).

**ЭСКИ'ЗНЫЙ** *живоп. книж.*—эскиздагы, эскиз характерындагы, эскиз рәвешендәге; *эскизный проект*—эскиз рәвешендәге проект.

**ЭСКИМО'** *ср. нескл.*— эскимо (шоколад белән хәзерләнгән морожный).

**ЭСКИМО'СКА** *ж.*— эскимос хатын-кызы.

**ЭСКИМО'ССКИЙ**—эскимос...-ы, эскимослар... ы; эскимосларча..., эскимосларга хас; *эскимосская одежда*—эскимослар киеме.

**ЭСКИМО'СЫ** *мн.*—эскимослар, эскимос халкы (Американың төньяк ярларында һәм Азиянең төньяк-көнчыгыш чигендә яшәүче халык).

**ЭСКО'РТ** *м. воен.*—эскорт (хәрби конвой, хәрби сакчылар отряды).

**ЭСКОРТИ'РОВАТЬ** *несов. воен.*— эскорт белән озату (алып бару), конвой белән озату (алып бару), сакчылар отряды белән озату (алып бару).

**ЭСКУЛА'П** *м. устар. шутл.*— эскулап, врач, табиб.

**ЭСМИ'НЕЦ** *м. воен. мор.*—эсминец (эскадра миноносецы).

**ЭСПАДРО'Н** *спорт.*—эспадрон (фехтованиедә кулланыла торган тупыйк очлы кылыч); *драться на эспадронах*—эспадроннар белән сугышу.

**ЭСПАНЬО'ЛКА** *ж.*— эспаньолка (очлаеп килгән кыска сакал).

**ЭСПАРЦЕ'Т** *м. мн.* нет, *бот.*— эспарцет (азык үлән).

**ЭСПЕРАНТИ'СТ** *м.*, **ЭСПЕРАНТИСТКА** *ж.*—эсперантист, эсперанто тарафдары, эсперанто телендә сөйләшүче кеше.

**ЭСПЕРА'НТО** *ср. нескл.*— эсперанто (Европаның төп телләре материалына нигезләнгән ясалма халыкара тел).

**ЭСПЛАНА'ДА** *ж.*—эспланада (**1.** *воен.* крепость белән шәһәр арасындагы буш, ачык урын; **2.** берәр бина каршындагы ачык урын, мәйдан).

**ЭССЕИ'СТ** *м. лит.*—к. очеркист.

**ЭССЕ'НЦИЯ** *ж.*— **1.** эссенция (**а.** сыгып алынган һәм су кушылып файдаланыла торган куе, көчле состав; **б.** төрле үсемлекләр, чәчәкләр, җимешләр салып төнәтелгән спирт); **2.** *перен. книж.* к. квинтэссенция.

**ЭСТАКА'ДА** *ж.*—эстакада (**1.** суднолар килеп туктау өчен яки берәр җирдәге хәрәкәтнең бик кызу чагында күчү, йөрү өчен субайлар өстенә ясалган күпер; **2.** су асты юлларына субайлар сугып ясалган киртә).

**ЭСТА'МП** *м.*—эстамп (гравюрадан төшереп алынган нөсхә).

**ЭСТАНДА'РТ-Ю'НКЕР** *м. воен. истор.*— эстандарт-юнкер (атлы гаскәрдә хәрби дәрәҗә; подпрапорщикка туры килә).

**ЭСТАФЕ'ТА** *ж.*—эстафета (**1.** *только ед. истор.* җәяүле яки атлы нарочныйлар аркылы йөртелә торган почта; **2.** *истор.* шушы почта белән җибәрелгән яки алынган хат, хәбәр; **3.** *спорт.* йөгерү, йөзү һ. б. буенча команда ярышларының бер төре; **4.** *спорт.* йөгерү ярышларында билгеле араны үткән саен йөгерүчеләр тарафыннан кулдан-кулга тапшырыла торган таякчык).

**ЭСТАФЕ'ТНЫЙ**—**1.** *истор.* эстафета...-ы, эстафета белән җибәрелгән; *эстафетное известие*—эстафета хәбәре, эстафета белән җибәрелгән хәбәр; **2.** *спорт.* эстафета...-ы, эстафеталы; *эстафетное соревнование* — эстафета ярышы.

**ЭСТЕ'Т** *м. книж.*—эстет, эстетизм тарафдары (сәнгатьтә бары тик тышкы нәфислеккә генә игътибар итүче кеше).

**ЭСТЕТИ'ЗМ** *м. мн.* нет, *книж.*—эстетизм (**1.** гүзәллеккә, нәфислеккә бирелгән булу, гүзәллеккә, нәфислеккә аеруча сизгер булу; **2.** *неодобр.* сәнгатьтә тышкы формаларга гадәттән тыш игътибар итеп, аның идея әһәмиятен икенче планга күчерү, төшерү; „саф сәнгать"кә бирелү).

**ЭСТЕ'ТИК** *м.*—эстетик (**1.** *книж.* гүзәл-

леккә, нәфислеккә бирелгән кеше, гүзәллекне, нәфислекне аерата сиземләүче кеше, гүзәллек, нәфислек тарафдары; **2.** *искус.* сәнгать теоретигы, сәнгать белгече.

**ЭСТЕ'ТИКА** *ж. мн.* нет—эстетика (**1.** *искус.* художестволы иҗаттагы, табигатьтәге һәм тормыштагы матурлыкның идея эчтәлеген һәм формаларын өйрәнүгә багышланган фәлсәфи тәгълимат; **2.** *книж.* берәр кешенең сәнгатькә булган карашлары системасы; **3.** *книж.* к. эстетизм).

**ЭСТЕТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*—эстетик, матурлык (гүзәллек) белән бәйләнгән; *эстетическое переживание* — эстетик кичереш; *эстетические взгляды* — эстетик карашлар; *эстетические функции слова*—сүзнең эстетик функцияләре.

**ЭСТЕТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*— **1.** матурлык, гүзәллек, нәфислек; *эстетичность фортепианных пьес Чайковского* — Чайковскийның фортепиано өчен язылган пьесаларының гүзәллеге; **2.** эстетизм белән сугарылганлык.

**ЭСТЕ'ТИЧНЫЙ** *книж.*— **1.** матур, гүзәл, нәфис; **2.** эстетизм белән сугарылган.

**ЭСТЕ'ТНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж. ирон.*— эстетлык рухы белән сугарылганлык, матурлыкка (гүзәллеккә) дәгъва кылучанлык, кыланчыклык.

**ЭСТЕ'ТНЫЙ** *книж. ирон.*—эстетлык рухы белән сугарылган, матурлыкка (гүзәллеккә) дәгъва кыла торган, кыланчык...; *эстетный молодой человек*—кыланчык егет.

**ЭСТЕ'ТСКИЙ** *книж. ирон.*— эстет...-ы, эстетлар...-ы; эстетка хас, эстетларга хас; *эстетские манеры* эстет кыланышлары, эстетларга хас кыланышлар.

**ЭСТЕ'ТСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. ирон.*— эстетлык, эстетизмга бирелгәнлек.

**ЭСТЕ'ТСТВОВАТЬ** *несов. книж. ирон.*— эстетларча эш итү, үз-үзеңне эстетларча тоту, эстетлык күрсәтү; *эстетствующий писатель*—эстетлык күрсәтүче язучы.

**ЭСТОКА'ДА** *ж. спорт.*— эстокада (фехтование кылычы белән перпендикуляр рәвештә сугу яки чәнчү алымы).

**Э'СТОЛЬ, Э'СТОЛЬКО** *нареч. простореч.*—менә шуның кадәр.

**ЭСТО'НКА** *ж.*—эстонка, эстон хатынкызы.

**ЭСТО'НСКИЙ** — эстон...-ы, эстоннар...-ы; эстонга хас, эстоннарга хас, эстоннарча...; *эстонская одежда*—эстоннар киеме.

**ЭСТО'НЦЫ** *мн.*— эстоннар, эстон халкы (Эстония ССРның төп халкы).

**ЭСТРАГО'Н** *м. мн.* нет, *бот. кулин.*— эстрагон (аш-суга тәм бирү өчен файдаланыла торган әрем).

**ЭСТРАГО'ННЫЙ** *бот. кулин.*— эстрагон...-ы, эстрагоннан хәзерләнгән; *эстрагонный уксус*—эстрагон серкәсе.

**ЭСТРА'ДА** *ж.*—эстрада (**1.** оркестр, җырчылар, аерым артистлар чыгышы өчен эшләнгән күтәренке мәйданчык, ачык сәхнә; **2.** *только ед. театр.* ачык сәхнәдә, эстрадада бирелгән концерт, тамаша).

**ЭСТРА'ДНЫЙ** — эстрада...-ы; *эстрадное искусство* — эстрада сәнгате; *эстрадный артист*—эстрада артисты.

**Э'СТЫ** *мн.*— к. эстонцы.

**Э'ТА** *м.*—к. этот.

**ЭТА'Ж** *м.*— **1.** кат, этаж; *дом в десять этажей* — ун катлы йорт, ун этажлы йорт; **2.** *перен. книж.* к. круг 4.

**ЭТАЖЕ'РКА** *ж.*—этажерка (шүрлекләр куеп ясалган ачык шкаф).

**ЭТА'ЖНОСТЬ** *ж. мн* нет, *спец.*—катлылык, этажлылык, катлар саны, этажлар саны, катларның биеклеге, этажларның биеклеге; *средняя этажность зданий на улице* — урамдагы йортларда этажларның уртача саны.

**ЭТА'ЖНЫЙ** — этаж...-ы, йорт каты...-ы этажга караган, һәрбер этажда була торган йортның һәрбер катында була торган; *этажный дежурный* — этаж дежурные; *этажный пролёт*—этаж арасы.

**Э'ТАК** *нареч. разг.*—**1.** алай, алай итеп, болай, болай итеп, шулай, менә болай, менә шулай; **2.** *в знач. ввод. сл.* чама белән әйткәндә, якынча; *лет, этак, девяносто ему было*—аңа, чама белән әйткәндә, туксан яшьләр булгандыр.

**Э'ТАКИЙ** *разг.*—**1.** мондый, менә мондый, шундый, менә шундый, андый; *да! счастье у кого есть эдакий сынок* (Грибоедов) — әйе! мондый малае булган кеше бәхетле; *этакое счастье ему привалило*—аңа шундый бәхет килде; **2.** нинди, кара нинди, шундый; *этакая неудача!*— нинди уңышсызлык!

**ЭТАЛО'Н** *м.*— эталон (**1.** *физ. тех.* кулланылуда булган үлчәү җайланмаларын тикшереп тору өчен хезмәт итүче үлчәү үрнәге; **2.** *перен. книж.* шаблон, калып, әзер калып).

**ЭТА'Н** *м. мн.* нет, *хим.*—этан (яктыртучы газда һәм нефть газында төссез, газсыман һәм янып китүчән матдә).

**ЭТА'П** *м.*—этап (**1.** *воен.* бер җирдән икенче җиргә күчкәндә хәрби командаларны, аерым хәрби хезмәткәрләрне квартира, азык-төлек, фураж белән тәэмин итә торган урын; **2.** *доревол.* бер җирдән икенче җиргә күчкәндә туктау пункты; **3.** *офиц.* берәр җиргә озатыла торган арестантлар группасы яки партиясе; **4.** *спорт.* спорт ярышларында дистанциянең билгеле өлеше; **5.** *перен. книж.* берәр процесс үсешендә аерым бер момент, стадия). ◇ **По этапу или этапом** *доревол. офиц.*—этап белән (патша Россиясе заманында арестантларны махсус конвой командаларының сакчылыгы астында озату турында әйтелә).

**ЭТА'ПНЫЙ**—этап...-ы; *этапный пункт*— этап пункты.

**Э'ТИКА** *ж. мн.* нет—этика (**1.** әхлак, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында фәлсәфи тәгълимат; **2.** аерым җәмгыять, иҗтимагый катлау яки профессия членнары арасында кабул ителгән әхлак, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре).

**ЭТИКЕ'Т** *м.*—этикет (**1.** *только ед.* дипломатлар арасында, патша сарайларында һ. б. кабул ителгән үзара мөнәсәбәт, үз-

үзеңне тоту кагыйдәләре; 2. *устар.* к. этикетка 1.)

**ЭТИКЕТА'Ж** *м. мн.* нет, *спец.*—этикетаж (1. музейларда, күргәзмәләрдә һ. б. экспонатлар өчен этикеткалар хәзерләү; 2. шушы этикеткалар системасы).

**ЭТИКЕ'ТКА** *ж.*— этикетка (1. сәүдә учреждениесе яки фабрика келәймәсе, маркасы яки берәр төрле язу белән товарга, нинди дә булса әйбергә беркетелгән ярлык; 2. *перен. разг. пренебр.* берәр кешегә яки берәр әйбергә шаблон буенча бирелгән характеристика).

**ЭТИ'Л** *м. хим.*—этил (күп кенә органик кушылмалар составына керә торган һәм углерод белән водород атомнарыннан торган бер группа).

**ЭТИЛЕ'Н** *м. мн.* нет, *хим.*—этилен (янып китүчән төче, тәмле исле газ).

**ЭТИМО'ЛОГ** *м. спец.*— этимолог, этимология белгече, этимология галиме.

**ЭТИМОЛОГИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *лингв.*—этимологизация (берәр сүзнең этимологиясен, килеп чыгуын билгеләү; гадәттә халык этимологиясе күренешләре, сүзләрнең килеп чыгу ягыннан бәйләнешләрен бары тик тышкы охшашлык буенча гына билгеләү турында әйтелә).

**ЭТИМОЛОГИЗИ'РОВАТЬ** *несов. лингв.*—этимологизация белән шөгыльләнү, сүзләрнең килеп чыгышын ачыклау белән шөгыльләнү.

**ЭТИМОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *лингв.*—этимологик, этимологиягә караган, этимология...-ы; *этимологические исследования* — этимологиягә караган тикшеренүләр; *этимологический словарь*—этимология сүзлеге.

**ЭТИМОЛО'ГИЯ** *ж. лингв.*—этимология (1. *только ед.* тел белемендә сүзләрнең килеп чыгуын өйрәнә торган бүлек; 2. теге яки бу сүзнең килеп чыгуы; 3. *только ед. устар.* мәктәп грамматикасының фонетика һәм морфология бүлекләре). ◇ **Народная этимология** *лингв.*— халык этимологиясе (башка телдән алынган сүзне үз ана телендәге берәр сүзгә охшатып үзгәртү яки шушы юл белән үзгәртелгән сүз; мәсәлән, „скупать" сүзе тәэсире белән „спекулянт" сүзен „скупулянт" дип үзгәртү).

**ЭТИОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *мед.*— этиологик, этиологиягә караган.

**ЭТИОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет— этиология (1. авыруның килеп чыгу сәбәпләре турындагы өйрәтмә; 2. авыруның килеп чыгу сәбәбе).

**ЭТИ'ЧЕСКИЙ** *книж.*— этик, этика...-ы, әхлак...-ы, әхлакый; *история этических учений*—этика тәгълиматлары тарихы; *этические взгляды*—әхлакый карашлар.

**ЭТИ'ЧНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*—этикалылык, әхлаклылык, әдәплелек; *этичность поведения*—үз-үзеңне тотуның әдәплелеге.

**ЭТИ'ЧНЫЙ** *книж.*—этикалы, әдәпле, әхлаклы, этикага ярашлы, әхлакка ярашлы.

**ЭТНИ'ЧЕСКИЙ** *науч.*—этник (нинди дә булса халыкның культурасына, гореф-гадәтләренә, көнкүрешенә бәйләнгән); *этнические элементы*—этник элементлар.

**ЭТНО'ГРАФ** *м.*—этнограф, этнография белгече, этнография галиме.

**ЭТНОГРАФИ'ЧЕСКИЙ**— этнографик, этнография...-ы (берәр халыкның культурасын, гореф-гадәтләрен, көнкүрешен тикшерүгә бәйләнгән); *этнографическая экспедиция*—этнографик экспедиция.

**ЭТНОГРА'ФИЯ** *ж. мн.* нет — этнография (1. аерым халыкларның көнкүреше, гореф-гадәтләре, материаль һәм рухи культурасы турындагы фән; 2. теге яки бу халыкның көнкүрешендәге, гореф-гадәтләрендәге, материаль һәм рухи культурасындагы үзенчәлекләр).

**ЭТНО'ЛОГ** *м. спец.*—этнолог, этнология белгече.

**ЭТНОЛОГИ'ЧЕСКИЙ** *спец.*— этнологик.

**ЭТНОЛО'ГИЯ** *ж. мн.* нет — этнология (халыклар, бигрәк тә борынгы халыклар турындагы фән).

**Э'ТО** I *частица*—1. *разг.* ул, бу; ...инде ул (алай, болай), алай, болай; *кто это там стучит?*—кем ул анда ишек кага? *как это так?*—ничек инде ул алай? *что это ты так весел?*—ничек син болай бик кәефле? *куда это он пошёл?*—кая китте ул болай? *и откуда это столько народу набралось* (Чехов)—каян болай бу кадәр күп халык җыелган?

**Э'ТО** II *ср.*—к. этот.

**Э'ТОТ**—1. бу, шушы, менә бу, менә шушы; *подай мне эту книгу* — миңа менә шушы китапны алып бир; *на этой стороне площади*—мәйданның бу ягында; 2. шул, шушы, бу, ул; *этот человек всегда причиняет мне только беспокойство* — бу кеше миңа гел мәшәкать кенә тудыра; 3. монысы, бусы; *выпил стакан, попросил другой, выпил и этот*—бер стакан эчте, икенчесен сорады, монысын да эчеп бетерде; *того не ест, этого не любит*—тегесен ашамый, монысын яратмый; 4. бу (вакыйга, хәл, эш, предмет һ. б.); *как это произошло?*—бу ничек булды, бу вакыйга ничек булды? *я этого не знаю*—мин моны белмим; *никто этому не поверит* — бу хәлгә (моңа) беркем дә ышанмас. ◇ **При этом**—шуның белән бергә, шуның белән бергәттән, өстәвенә, шуның өстенә; *при этом он еще и глух*—өстәвенә (шуның өстенә) ул әле чукрак та.

**ЭТУА'ЛЬ** *ж. устар.*—этуаль (оперетта кебек җиңел жанрларда катнашучы актриса).

**ЭТЮ'Д** *м.*—этюд (1. төп сызыклары гына төшерелгән яки эшләнгән, соныннан тулы бер композицион бөтеннең билгеле кисәген тәшкил итәрлек рәсем, скульптура әсәре һ. б.; 2. *книж.* әдәби, гыйльми яки философик очерк; 3. музыкада, шахмат яки шашка уеннарындагы күнегүләрнең бер төре; 4. *муз.* кечкенә күләмле музыкаль әсәр).

**ЭТЮ'ДНИК** *м. спец.*—этюдник (этюд характерындагы рәсемнәр папкасы).

**ЭТЮ'ДНЫЙ**—этюд...-ы; *этюдный жанр*—этюд жанры; *этюдное упражнение* — этюд күнегүе.

**ЭФЕ'ДРА** *ж. бот.*— эфедра (дала кура җиләге; медицинада кулланыла).

**ЭФЕМЕРИ'ДА** *ж.*—**1.** *зоол.* к. однодневка; **2.** эфемерида (**а.** *астр. только мн.* ай яки елның билгеле бер көннәрендә күк яктырткычларының торышын күрсәткән астрономик таблица; **3.** *перен. книж.* нинди дә булса тиз үтүчән, даими булмаган, тиз бетә торган бер нәрсә, хәл яки вакыйга).

**ЭФЕМЕ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*—эфемерлык, тиз үтүчәнлек, даими булмаганлык.

**ЭФЕМЕ'РНЫЙ** *книж.*— эфемер, тиз үтүчән, даими булмаган, тиз бетә торган; *эфемерные достижения*—тиз үтүчән уңышлар.

**ЭФЕНДИ** *м. нескл.*—эфәнде.

**ЭФЕ'С** *м.*—кылыч (хәнҗәр) сабы, кылыч (хәнҗәр) тоткасы.

**ЭФЕ'СНЫЙ** – кылыч (хәнҗәр) сабы...-ы, кылыч (хәнҗәр) тоткасы...-ы; *эфесные украшения*—кылыч сабы бизәкләре.

**ЭФИО'П** *м.*—**1.** абиссинияле, эфиопияле, хәбәш, хәбәшстанлы, Хәбәшстан кешесе; **2.** *устар.* негр, кара тәнле кеше.

**ЭФИО'ПКА** *ж.*— абиссинияле хатын-кыз, эфиопияле хатын-кыз, хәбәш хатын-кызы.

**ЭФИО'ПСКИЙ**—**1.** эфиоп (абиссин, хәбәш)...-ы, эфиоплар (абиссиннәр, хәбәшләр)...-ы; *эфиопское племя*—хәбәш кабиләсе; **2.** *простореч. бран. устар.* юньсез, аңгыралар...-ы; юньсезләргә (аңгыраларга) хас; *эфиопский поступок*—аңгыралар кыланышы, юньсез кыланышлар.

**ЭФИ'Р** *м. мн.* нет—эфир (**1.** борынгы грек философлары өйрәтмәләрендә бөтен галәмне тутырып торучы һәм төп „дүрт стихия"дән: уттан, һавадан, судан, туфрактан үзгә булган материя „бишенче стихия"; **2.** *перен. поэт.* биеклек, күк, бушлык, һатиф; **3.** медицинада, производствода һ. б. кулланыла торган бик тиз очып бетүчән сыекча).

**ЭФИ'РНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*—нәфислек, сәмавилек, җиңеллек.

**ЭФИ'РНЫЙ**—**1.** *хим. тех. мед.* эфир...-ы; эфирдан эшләнгән, эфирдан хәзерләнгән; *эфирное масло* — эфир мае; **2.** *перен. ирон. шутл.* нәфис, сәмави, җиңел, „өф" дисәң күккә очып китәргә хәзер торган; *эфирное существо*—„өф" дисәң күккә очып китәргә хәзер торган бер зат.

**ЭФИРОМА'Н** *м. мед.*—эфироман (эфиромания белән авыручы).

**ЭФИРОМА'НИЯ** *ж. мн.* нет, *мед.*—эфиромания (үз үзенне эфир белән исертүгә омтылу авыруы).

**ЭФИРОМА'НКА** *ж. мед.*—к. эфироман.

**ЭФФЕ'КТ** *м.*—**1.** *только ед.* эффект, тәэсир, көчле тәэсир, йогынты; *произвести эффект*—көчле тәэсир ясау; **2.** *только ед. книж. спец.* эффект, нәтиҗә, файда; *лекарство не дало никакого эффекта*—дару бернинди дә нәтиҗә бирмәде; **3.** эффект (нинди дә булса тәэсир ясауга ярдәм итүче нәрсәләр турында әйтелә); *сценические эффекты*- сәхнә эффектлары.

**ЭФФЕКТИ'ВНОСТЬ** *ж. мн.* нет, *книж.*—эффективлык, эффект бирүчелек, нәтиҗәлелек (файдалылык), нәтиҗә (файда) бирүчелек.

**ЭФФЕКТИ'ВНЫЙ** *книж.*— эффектив, эффект бирүче, нәтиҗәле (файдалы), нәтиҗә (файда) бирүче.

**ЭФФЕ'КТНОСТЬ** *ж. мн.* нет—эффектлылык, эффект ясый торганлык, (көчле) тәэсир ясый торганлык, тәэсир итүчәнлек.

**ЭФФЕ'КТНЫЙ** — эффектлы, эффект ясый торган, (көчле) тәэсир ясый торган, тәэсир итүчән; *эффектная поза* — эффектлы поза.

**ЭХ** *простореч. междом.*—их, әй, эх, их, ма; *эх, ты, разиня!*—их, син, ачык авыз! (их син, бу кадәр ачык авыз булырсың икән!)

**ЭХЕ'** *междом.*—әһә, ә-һә-һә, менә ничек, менә ничек икән.

**ЭХЕХЕ'** *междом.*—ай-һай, ай-һай-һай.

**ЭХИНОКО'КК** *м. зоол. мед.*— эхинококк (**1.** эт эчәкләрендә яши торган тасма суалчанның бер төре; **2.** шушы суалчанның хайван һәм кеше органнарында яши торган һәм күп кенә очракларда каты авыруга сәбәп була торган личинкасы).

**ЭХ-МА'** *простореч. междом.*—к. эх.

**Э'ХО** *ср. мн.* нет — яңгырык, тавыш яңгыравыгы, кайтаваз, кайтарма аваз (кире кайтып ишетелгән тавыш).

**ЭШАФО'Т** *м.*— эшафот (үлем җәзасын гамәлгә ашыру өчен ясалган махсус урын).

**ЭШЕЛО'Н** *м.*— эшелон (**1.** *воен.* фронт буенча яки тыл эченә таба урнашкан гаскәри берләшмә; **2.** *воен.* походтагы яки берәр жиргә күчеп баручы гомуми колоннаның аерым өлеше, гаскәри бүлеге; **3.** хәрби йөк яки гаскәр алып бара торган поезд; **4.** гомумән, махсус тапшыру буенча йөк яки кешеләр төяп баручы поезд).

**ЭШЕЛОНИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. воен.*—эшелонлаштыру, эшелон-эшелон итеп урнаштыру, эшелоннарга бүлү; *эшелонировать колонну*—колоннаны эшелон-эшелон итеп урнаштыру.

**ЭШЕЛОНИ'РОВАТЬСЯ** *несов. страд. воен.*— эшелонлаштырылу, эшелон-эшелон итеп урнаштырылу, эшелоннарга бүленү.

**ЭШТАФЕ'ТА** *ж. устар.*—к. эстафета.

# Ю

**ЮБИЛЕ'Й** *м.*— юбилей; *двадцатипятилетний юбилей ученого*— галимнең егерме биш еллык юбилее.

**ЮБИЛЕ'ЙНЫЙ** — юбилей ...-ы; юбилей уңае белән эшләнгән (хәзерләнгән, чыгарылган һ. б.); *юбилейные торжества* — юбилей тантаналары; *юбилейный сборник*—юбилей уңае белән чыгарылган җыентык.

**ЮБИЛЯ'Р** *м.*—юбиляр (юбилее уздырыла торган кеше яки учреждение).

**ЮБИЛЯ'РКА, ЮБИЛЯ'РША** *ж. разг. фам.*—к. юбиляр.

**Ю'БКА** *ж.*—1. юбка; 2. *перен. только ед. разг. фам.* юбка, хатын-кыз; *каждая юбка тебе милее жены* (Лейкин) —һәр очраган юбка сиңа үз хатыныңнан ягымлырак. ◇ **За юбку держаться** *разг. фам. шутл. перен.*—чабуга тотынып бару (бөтен очракларда да кемгә булса буйсынып яшәү).

**Ю'БОЧНИК** *м. разг. фам.*—хатын-кыз артыннан өстерәлүче кеше, хатын-кыз белән чуалучан кеше.

**Ю'БОЧНИЦА** *ж.*—юбка тегү остасы.

**Ю'БОЧНЫЙ** — юбка ...-ы; *юбочный покрой*—юбка өлгесе.

**ЮВЕЛИ'Р** *м.*—ювелир (1. кыйммәтле ташлардан һәм металлардан төрле кыйммәтле әйберләр ясау остасы; 2. шундый әйберләр белән сату итүче).

**ЮВЕЛИ'РНЫЙ** — 1. ювелир товарлар...-ы; *ювелирный магазин*— ювелир товарлар магазины; 2. ювелир...; *ювелирные товары* — ювелир товарлар; 3. нечкә эшләнгән, нәфис башкарылган; *ювелирная работа* — нәфис башкарылган эш.

**ЮГ** *м. мн.* нет— көньяк; *окна дома выходят на юг*—өйнең тәрәзәләре көньякка карыйлар; *жители юга*— көньякта торучылар.

**ЮГО-ВОСТО'К** *м. мн.* нет— көньяк-көнчыгыш; *держать курс на юго-восток* — көньяк-көнчыгышка курс тоту, көньяк-көнчыгышка юл тоту (таба бару).

**ЮГОВОСТО'ЧНЫЙ** —1. көньяк-көнчыгыш ...; *юговосточное направление* — көньяк-көнчыгыш юнәлеш; 2. көньяк-көнчыгыш...-ы; *юговосточный ветер* — көньяк-көнчыгыш җиле.

**ЮГО-ЗА'ПАД** *м. мн.* нет — көньяк-көнбатыш; *держать курс на юго-запад* — көньяк-көнбатышка курс тоту, көньяк-көнбатышка (таба) юл тоту.

**ЮГОЗА'ПАДНЫЙ** — 1. көньяк-көнбатыш...; *югозападное направление* — көньяк-көнбатыш юнәлеш; 2. көньяк-көнбатыш...-ы; *югозападный ветер* — көньяк-көнбатыш җиле.

**ЮГОСЛА'ВСКИЙ** — Югославия...-ы; *югославские народы* — Югославия халыклары.

**ЮГОСЛА'ВЫ** *мн.*— югославлар, Югославия халыклары.

**ЮГУ'РТ** *м. мн.* нет — югырт, болгар катыгы.

**Ю'ДО**: **чудо-юдо** — к. чудо.

**ЮДО'ЛЬ** *ж. мн.* нет: **земная юдоль, юдоль плача, юдоль печали** *устар.* — авыр тормыш, кайгы-хәсрәтле тормыш.

**ЮДОФИ'Л** *м. книж.*— юдофил (еврейләргә яхшы күз белән караучы, еврейләрне яратучы).

**ЮДОФИ'ЛЬСКИЙ** *книж.*— юдофиллык ...-ы; юдофиллар ...-ы, юдофилларга хас; еврейләргә яхшы күз белән карау...-ы; *юдофильская политика* — юдофиллар политикасы.

**ЮДОФИ'ЛЬСТВО** *ср. мн.* нет, *книж.*— юдофиллык.

**ЮДОФО'Б** *м. книж.*— юдофоб (еврейләргә нәфрәт белән караучы), антисемит.

**ЮДОФО'БСКИЙ** *книж.*— юдофоб...-ы; юдофоблар...-ы; юдофобларча..., юдофобларга хас; еврейләргә дошман кеше ...-ы; *юдофобский взгляд* — юдофоблар карашы, юдофобларча караш.

**ЮДОФО'БСТВО** *ср. мн.* нет — юдофоблык (еврейләргә нәфрәт белән карау), антисемитизм.

**ЮЖА'НИН** *м.*, **ЮЖА'НКА** *ж.*— көньяк кешесе.

**Ю'ЖНЫЙ** —1. көньяк ...; көньяк...-ы; *южный полюс* — көньяк полюс, көньяк котып; *южное солнце* — көньяк кояшы; 2. кайнар, көньяк кешеләренә хас; *южный темперамент* — кайнар темперамент.

**ЮЗ** *м. спец.*— юз (телеграф аппараты); *передать депешу по юзу* — телеграмманы юз аркылы тапшыру.

**ЮЗИ'СТ** *м. спец.*— юзист (юзда эшләүче телеграфист).

**Ю'ЗОМ** *нареч.*— җирдән өстерәп, җирдән сөйрәп; *передвигать груз юзом* — йөкне җирдән өстерәп күчерү.

**ЮКАГИ'РСКИЙ** — юкагир ...-ы, юкагирлар ...-ы; *юкагирский язык* — юкагир теле.

**ЮКАГИ'РЫ** *мн.*— юкагирлар, юкагир халкы (Якутиядә яшәүче халыкларның берсе).

**Ю'ККА** *ж. мн.* нет — юкка (1. *бот.* лаләчәләр семьялыгына караган үсемлек; 2. шушы үсемлекнең сусе).

**ЮЛА'** *ж.*—1. бөтерчек, зырылдавык (уенчык); 2. *перен. только ед. разг.* тиктормас (кеше), кыбырсык (кеше); 3. *зоол.* урман тургае.

**ЮЛИА'НСКИЙ**: **юлианский календарь, юлианское летоисчисление**—юлиан календаре, юлиан ел исәбе, иске стильдәге календарь, иске стильдәге ел исәбе (Октябрь революциясенә кадәр Россиядә ел исәбе шул стильдә йөртелә иде).

**ЮЛИ'ТЬ** *несов. разг.*—1. бөтерелү, ыгы-зыгы килү; *под носом юлит муха* — борын төбендә чебен бөтерелә; 2. *перен.* ялагайлану, тәлинкә тоту, ялагайланып бөтерелү (кемнең дә булса каршында); *юлить перед начальником* — начальник каршында ялагайлану.

**Ю'ЛКА** *ж. зоол.*— к. юла 3.

**Ю'МОР** *м. мн.* нет —1. юмор, көлке; *говорить с юмором* — юмор белән сөйләү; 2. юмор, көлкеле әсәрләр; *юмор и сатира*— юмор һәм сатира. ◇ **Юмор висельника** *ирон.*— һәлакәт алдында торучы кешенең (тапкыр) шаян сүзләре.

**ЮМОРЕ'СКА** *ж. лит. искус.*— юмореска (кечкенә күләмле көлкеле әсәр); *музыкальная юмореска* — музыкаль юмореска.

**ЮМОРИ'СТ** *м.*—1. *лит. искус.* юморист, юмористик әсәрләр авторы; *Чехов принадлежит к числу величайших юмористов Европы* — Чехов Европаның иң бөек юмористларыннан санала; 2. мәзәкчән кеше, юмор белән сөйләргә яратучы кеше.

**ЮМОРИ'СТИКА** *ж. мн.* нет —1. *лит. искус.* юмористика, көлкеле әсәрләр, юмо-

ристик әсәрләр; *театральная юмористика* — юмористик театраль әсәрләр; 2. *разг.* көлке, мәзәк, юмористика; *эта какая-то юмористика, а не научное исследование* — бу ниндидер көлке генә (юмористика гына), фәнни тикшеренү түгел.

**ЮМОРИСТИ'ЧЕСКИЙ** — юмористик, көлкеле; *юмористическая литература* — юмористик әдәбият.

**ЮМОРИ'СТКА** *ж.* — к. юморист.

**Ю'НГА** *м. мор.* — юнга (матрос булырга хәзерләнүче яшүсмер).

**ЮНЕ'ТЬ** *несов. книж.* — яшәрү, яшәрә бару.

**ЮНЕ'Ц** *м. книж. устар. пренебр.* — яшүсмер, малай.

**ЮНИ'ЦА** *книж. устар.* — үсмер кыз, кызчык.

**Ю'НКЕР** *м.* — юнкер (1. *истор.* элекке Пруссиядә җир биләүче эре алпавыт; 2. *воен. дореvол.* патша Россиясендә хәрби урта мәктәп укучысы; 3. *воен. истор.* дворян нәселеннән булган рядовой яки унтер-офицер).

**Ю'НКЕРСКИЙ** —1. юнкерлык ...-ы; юнкер...-ы, юнкерлар ...-ы; *юнкерское училище* — юнкерлар училищесы; *юнкерское звание* — юнкерлык дәрәҗәсе; 2. *истор.* юнкер ...-ы, эре алпавыт...-ы; *юнкерское хозяйство* — эре алпавыт хуҗалыгы (элекке Пруссиядә).

**Ю'НКЕРСТВО** *ср. мн.* нет —1. *собир. истор.* юнкерлар (элекке Пруссиядә эре алпавытлар); 2. *воен.* юнкерлык дәрәҗәсе.

**ЮНКЕРЬЁ** *ср. мн.* нет, *собир. простореч. презрит.* — юнкерлар; *с юнкерьём гуляла* — юнкерлар белән типтереп йөрдем (ең, е).

**ЮНКО'Р** (юный корреспондент) *м.* — яшь хәбәрче.

**ЮНКО'РОВСКИЙ** — яшь хәбәрчеләр ...-ы, яшь хәбәрче ...-ы; *юнкоровское движение* — яшь хәбәрчеләр хәрәкәте.

**ЮННА'Т** (юный натуралист) *м.* — яшь натуралист.

**ЮННА'ТОВСКИЙ** — яшь натуралистлар ...-ы, яшь натуралист ...-ы; *юннатовское движение* — яшь натуралистлар хәрәкәте.

**Ю'НОСТЬ** *ж. мн.* нет — яшьлек, яшь чак, яшүсмер чак; *счастливая юность* — бәхетле яшьлек.

**Ю'НОША** *м.* — яшүсмер, яшь егет.

**Ю'НОШЕСКИЙ** —1. яшьлек ...-ы; *юношеские мечты* — яшьлек хыяллары; *юношеский задор* — яшьлек дәрте; 2. яшьләр ...-ы; *юношеское рабочее движение* — яшь эшчеләр хәрәкәте.

**Ю'НОШЕСТВО** *ср. мн.* нет —1. яшь чак, яшүсмер чак, яшьлек, *его юношество было счастливо* — аның яшь чагы бәхетле иде; 2. *собир.* яшьләр, яшүсмерләр; *движение юношества в капиталистических странах* — капиталистик илләрдә яшьләр хәрәкәте.

**ЮНСЕ'КЦИЯ** *ж.* — яшьләр секциясе.

**Ю'НЫЙ** *книж.*—1. яшь; *юный герой* — яшь герой; *юные пионеры* — яшь пионерлар; 2. яшьләргә хас, яшьлеккә хас, яшь чакка хас, яшьлек ...-ы; *юный задор* — яшьлек дәрте.

**ЮПИ'ТЕР** *м. тех.* — юпитер (бик куәтле яктыртучы прибор, прожекторның бер төре); *теплоход освещается юпитерами* — теплоход юпитерлар белән яктыртыла.

**ЮР: на юру, на самом юру** — к. на юру.

**ЮРИДИ'ЧЕСКИ** *нареч.* — юридик, юридик яктан; *юридически он прав* — юридик яктан ул хаклы.

**ЮРИДИ'ЧЕСКИЙ** —1. юридик, хокук ...-ы; *юридические науки* — юридик фәннәр; *юридический факультет* — хокук факультеты. ◇ **Юридическое лицо** — к. лицо.

**ЮРИСДИ'КЦИЯ** *ж. мн.* нет, *право* — юрисдикция (1. хөкем итә алу хокукы; *обладать юрисдикцией* — юрисдикциягә ия булу, хөкем итә алу хокукына ия булу; 2. шушы хокук карамагына буйсынган өлкә, кайсы эшнең кайсы судта каралырга тиешлеге; *подлежать чьей-нибудь юрисдикции* — кемнең дә булса юрисдикциясендә булу, кемнең дә булса хөкем итә алу хокукы карамагында булу.

**ЮРИСКО'НСУЛЬСТВО** *ср. мн.* нет — юрисконсультлык хезмәте, юрисконсультлык.

**ЮРИСКО'НСУЛЬТ** *м.* — юрисконсульт (нинди дә булса учреждениенең хокук мәсьәләләре буенча консультанты, киңәшчесе).

**ЮРИСКО'НСУЛЬТСКИЙ** — юрисконсультлык...-ы, юрисконсульт ...-ы; *юрисконсультские обязанности* — юрисконсульт вазифалары.

**ЮРИСПРУДЕ'НЦИЯ** *ж. мн.* нет — юриспруденция, хокук белеме, хокук фәннәре; *заниматься юриспруденцией* — юриспруденция белән шөгыльләнү.

**ЮРИ'СТ** *м.* — юрист (1. хокук белгече; *он юрист по образованию* — ул белеме буенча юрист; 2. *разг.* хокук факультеты студенты).

**ЮРК** *в знач. сказ. разг.* — сызды (м, н), шылды(м, н), ялт итеп чыгып (кереп) китте(м, н); *юрк в дверь* — ишектән ялт итеп чыгып китте.

**Ю'РКИЙ** —1. тере, җитез, елгыр, елдам; *юркое движение* — җитез хәрәкәт; *юркая мышь* — елгыр тычкан; 2. *разг. неодобр. перен.* хәйләкәр, шома, тыкшынучан; *очень юркий человек* — бик шома кеше.

**Ю'РКНУТЬ** *сов. разг.* — бик тиз кереп (чыгып) югалу, елт итеп кереп (чыгып) югалу, күз ачып йомганчы кереп (чыгып) югалу, сызу, шылу; *мышь юркнула в щель* — тычкан елт итеп ярыкка кереп югалды.

**Ю'РКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *разг.* — җитезлек, тизлек, елдамлык; *юркость движения* — хәрәкәтләрнең җитезлеге.

**ЮРО'Д** *м. разг.* — к. юродивый 2.

**ЮРО'ДИВЫЙ** —1. юләрсымак, акылсыз; 2. *в знач. сущ. церк. религ.* гаиптән хәбәр бирүче дивана.

**ЮРО'ДСКИЙ** *разг.* — дивана...-ы, дивана

кеше...-ы, юләр кеше ...-ы; *юродские выверты* — дивана кеше кыланышлары.

**ЮРО'ДСТВО** *ср.*—1. дивана булып кылану, диваналану, юләр булып кылану, юләрсыман кылану, акылсызлану; 2. юләрлек, акылсызлык, тинтәклек, диваналык; *совершать юродства* — акылсызлыклар эшләү.

**ЮРО'ДСТВОВАТЬ** *несов.*— 1. юләр булу, дивана булу, акылсыз булу; 2. юләрлекләр эшләү, диваналыклар эшләү, акылсызлыклар эшләү.

**ЮРО'К** *м. зоол. обл.*— к. вьюрок.

**Ю'РСКИЙ** *геол.*— юр ...-ы; *юрский период* — юр дәвере (мезозой эрасының икенче дәвере); *юрский известняк* — юр известь-ташы.

**Ю'РТА** *ж.*— тирмә, киез өй (күчмә халыкларда).

**Ю'РЬЕВ ДЕНЬ** *м. мн.* нет, *истор.*— Юрий көне (крепостной крестьяннарның бер алпавыттан икенче алпавытка күчә алу көне). ◇ **Вот тебе, бабушка, и Юрьев день!**— менә сиңа кирәк булса! (көтелмәгән хәл булганда яки уңышсызлыкка очраганда әйтелә).

**ЮС** *м.*— 1. юс (борынгы славян азбукасында ике борын сузыгының исеме); 2. *устар. шутл. бран.* закончы, законнарны үз файдасына боргалаучы, суд-полиция эшләрен белүче кеше.

**ЮСТИ'РНЫЙ** *тех.*— к. юстировальный.

**ЮСТИРОВА'ЛЬНЫЙ** *тех.*—тигезләү...-ы, туры китерү...-ы, җайлау ...-ы, көйләү ...-ы, дөресләү...-ы; *юстировальный станок* — көйләү станогы.

**ЮСТИРОВА'ТЬ** *сов.* и *несов. тех.*— тигезләү, туры китерү, җайлау, көйләү, дөресләү; *юстировать инструмент*— инструментны көйләү.

**ЮСТИРОВА'ТЬСЯ** *несов. страд. тех.*— тигезләнү, туры китерелү, җайлану, көйләнү, дөресләнү.

**ЮСТИ'ЦИЯ** *ж. мн.* нет — юстиция (1. закон буенча, хокук кагыйдәләре буенча суд эшләре алып бару; 2. суд учреждениеләре системасы); *министерство юстиции* — юстиция министрлыгы.

**ЮТ** *м. мор.*— ют (судннода югары палубаның арткы өлеше).

**ЮТИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. урнашу, җайлашып урнашу; *на берегу ютится село* —яр буена авыл урнашкан; 2. тору, сыену, сыенып тору; *зимой я ютился у знакомых*— кышын мин танышларда сыенып тордым.

**Ю'ФЕРС** *м. мор.*— юферс (суднода такелаж тарттыру өчен кулланыла торган чыгыр).

**Ю'ФТА** *ж. мн.* нет — к. юфть.

**Ю'ФТЕВЫЙ** *спец.*— юфтьтән тегелгән, эшләнгән, йомшак күннән (тегелгән) эшләнгән.

**ЮФТЬ** *ж. мн.* нет, *спец.*— юфть, йомшак күн; *сапоги из юфти* — юфтьтән тегелгән итек, йомшак күннән тегелгән итек.

**ЮФТЯНО'Й** *спец.*— к. юфтевый.

# Я

**Я** — 1. мин; *я приду завтра* — мин иртәгә килермен; 2. *в знач. сущ. нескл. ср.*— шәхес, мин; *моё второе „я"* — минем икенче „мин"ем. ◇ **Не я буду, если...** — әгәр ...-мәсәм, исемем ... булмасын, әгәр ...-мәсәм, җир упсын; *не я буду, если не добьюсь своего* — әгәр үземнекен итмәсәм, исемем ... булмасын. **Я тебе дам** — кирәгеңне бирермен, мин сиңа күрсәтермен. **Я тебе (те, вам)** *разг.*—...мин сиңа (сезгә); *я тебе поваляюсь на диване!* — диванда аунармын мин сиңа! диванда аунарга бирермен мин сиңа!

**Я'БЕДА** *разг.*— 1. *ж.* әләк, яла; *заниматься ябедой* — әләкләү, әләкләргә ярату; 2. *ж. устар.* (судка тапшырыла торган) үтенеч, заявление; *писать ябеды* — үтенечләр язу; 3 *м.* и *ж. разг.* к. ябедник.

**Я'БЕДНИК** *м.*— 1. әләкче, яла ягучы; 2. *устар.* (судлашып, буташтырып) даулашып йөрүче кеше.

**Я'БЕДНИЦА** *ж.*— к. ябедник 1.

**Я'БЕДНИЧАТЬ** *несов.*— әләкләү, әләкләп (әләкләшеп) йөрү, яла ягып йөрү.

**Я'БЕДНИЧЕСКИЙ** — әләкче...-ы, әләкләү...-ы; *ябеднические замашки* — әләкче кыланышлары.

**Я'БЕДНИЧЕСТВО** *ср. мн. нет.*— 1. әләкләү, әләкләп (әләкләп) йөрү, яла ягу, яла ягып йөрү; 2. *устар.* (судлашып, буташтырып) даулашып йөрү.

**Я'БЛОКО** *ср.*— алма; *спелое яблоко* — пешкән алма. ◇ **Адамово яблоко** — к. кадык. **В яблоках** — алмачуар (ат төсе). **Глазное яблоко** — күз алмасы. **Яблоко раздора** — ызгышка, җәнҗалга сәбәп булган нәрсә, ызгыш сәбәбе, җәнҗал сәбәбе. **Яблоку негде упасть** *разг. перен.*— аяк басарлык та урын юк, инә төшәрлек тә урын юк, бик тыгыз.

**Я'БЛОНЕВЫЙ** — 1. алма ...-ы; *яблоневые сады* — алма бакчалары; 2. алмагач ...-ы; *яблоневая ветка* — алмагач ботагы.

**Я'БЛОННЫЙ** — к. яблоневый.

**Я'БЛОНЯ** *ж.*— алмагач; *дикая яблоня*— кыргый алмагач.

**Я'БЛОЧНИК** *м.*, **Я'БЛОЧНИЦА** *ж. устар.*— алма сатучы, алма белән сәүдә итүче.

**Я'БЛОЧНЫЙ** — алма ...-ы; *яблочная кожица* — алма кабыгы; *яблочный вкус* — алма тәме; *яблочный пирог* — алма бәлеше.

**ЯВИ'ТЬ** *сов. устар.*— 1. күрсәтү, белдерү; *явить пример мужества* — батырлык үрнәге күрсәтү; 2. *канц.* тапшыру, күрсәтү; *явить паспорт в полицию* — полициягә паспорт тапшыру.

**ЯВИ'ТЬСЯ** *сов.*— 1. килү, килеп җитү, килеп күренү; *явиться по приказанию* — приказ буенча килү; *во время явиться на заседание* — утырышка вакытында килеп җитү; *поздно явился к вам* — сезгә бик соң килдем; 2. килеп чыгу, күренү, пәйда булу, калкып чыгу; *он опять явился у Чекалинского* (Пушкин) — ул тагын Чекалинскийга килеп чыккан; 3. туу, барлыкка килү; *явилась мысль* — фикер туды; 4. *книж.* булу, булып чыгу; *это явилось для нас полной неожиданностью* — бу безнең өчен һич көтелмәгән бер хәл булып чыкты.

**Я'ВКА** *ж.*— 1. *офиц.* килү; *явка на собрание обязательна* — җыелышка килү мәҗбүри; 2. *канц. устар.* тапшыру, күрсәтү; *явка паспорта на прописку* — паспортны прописакага тапшыру; 3. *полит.* яшерен очрашу, яшерен очрашу урыны; *дать комунибудь явку* — кемгә дә булса яшерен очрашу, урынын билгеләү, (белдерү); 4. *полит.* пароль, яшерен очрашу вакытларында шартлы билге, яшерен сүз; 5. *устар.* (хөкүмәт органнарына) хәбәр итү, белдерү; *явка о краже* — урлау турында белдерү.

**ЯВЛЕ'НИЕ** *ср.*— 1. *книж. устар. церк.* пәйда булу, күренү, килеп чыгу, калкып чыгу; *явление Христа ученикам* — Гайсаның үз шәкертләре алдында пәйда булуы; 2. *лит. театр.* күренеш, манзара; *действие третье, явление пятое* — өченче пәрдә, бишенче күренеш; 3. күренеш; *явления природы* — табигать күренешләре; 4. вакыйга, хәл; *странное явление* — гаҗәеп вакыйга, гаҗәп хәл.

**ЯВЛЯ'ТЬ** *несов. устар.*— күрсәтү, күрсәтеп тору, белдерү, белдереп тору; *тут соловей являть свое искусство стал* (Крылов) — шул чакта сандугач үзенең һөнәрен күрсәтергә тотынды.

**ЯВЛЯ'ТЬСЯ** *несов.*— 1. килү, килеп чыгу, күренү, күренеп йөрү, туу, калкып чыгу, пәйда булу; 2. булу, булып тору; *это является новым доказательством дружбы* — бу — дуслыкның яңа дәлиле, бу — дуслыкның яңа дәлиле булып тора; 3. *страд. устар.* күрсәтелү, белдерелү.

**ЯВНОБРА'ЧНЫЕ** *мн. бот. устар.*— ачык аталанучылар (үсемлекләр).

**Я'ВНЫЙ** — ачык, ачыктан-ачык, күзгә бәрелеп торган, көн кебек ачык, бәхәссез; *явная вражда* — ачыктан-ачык дошманлык; *явное противоречие* — күзгә бәрелеп торган капма-каршылык.

**Я'ВОР** *м.*— явор, чинар, ак чаган (агач).

**Я'ВОРОВЫЙ** — явор ...-ы, чинар ...-ы, ак чаган ...-ы; *яворовые цветы* — явор чәчәкләре.

**Я'ВОЧНЫЙ** — 1. *полит.* яшерен очрашу ...-ы; *явочная квартира* — яшерен очрашу квартирасы; 2. *устар.* (хөкүмәт органнарына) хәбәр итү (белдерү)...-ы; *явочный лист* — хәбәр итү кәгазе.◇**Явочный порядок** *право* — дәүләт тарафыннан алдан рөхсәт алмыйча төрле җәмгыятьләр, оешмалар төзү, җыелышлар үткәрү тәртибе.

**Я'ВСТВЕННЫЙ** — ачык, ап-ачык, аңлаешлы, күзгә бәрелеп торган, аермачык ишетелеп (күренеп) торган; *явственные звуки* — аермачык ишетелеп торган авазлар.

**Я'ВСТВОВАТЬ** *несов. книж. канц.*— күренү, килеп чыгу, күренеп тору; *из этого явствует следующее* — моңардан түбәндәгеләр (күренә) килеп чыга.

**ЯВЬ** *ж. мн.* нет — өн; *сон и явь* — төш һәм өн.

**ЯГА'** *ж. мн.* нет — к. баба-яга.

**ЯГДТА'Ш** — аучылар сумкасы.

**Я'ГЕЛЬ** *м. мн.* нет, *бот.* — ягель, болан мүге (боланнар ашый торган мүк).

**ЯГНЁНОК** *м.*— бәрән, сарык бәрәне, бәти, кузы.

**ЯГНИ'ТЬСЯ** *несов.*— бәрәнләү, бәтиләү, бәрән китерү (сарык турында).

**ЯГНЯ'ТНИК** *м. зоол.*— бәрәнкарак, бәрән бөркете.

**ЯГНЯ'ЧИЙ** — бәрән ...-ы, сарык бәрәне...-ы, бәти ...-ы, кузы ...-ы; *ягнячья шерсть* — бәрән йоны.

**Я'ГОДА** *ж.*— җиләк, җимеш, җиләк-җимеш; *собирать ягоды* — җиләк җыю.◇**Винная ягода — инҗир (җимеше). Волчья ягода — бүре җиләге, карга миләше. Нашего (одного, своего) поля ягода** *разг. фам.*— безнең кеше, үз кеше, безнең белән бертигез кеше.

**Я'ГОДИЦА** *ж.*— 1. *только мн.* арт сан; 2. арт санның бер ягы; 3. (хатын-кызларда) имчәк имезлеге.

**Я'ГОДИЧНЫЙ** — арт сан ...-ы; *ягодичные мышцы* — арт сан мускуллары.

**Я'ГОДНИК** *м.*— 1. җиләклек, җиләкле урын, җиләк-җимеш бакчасы; *отыскать в лесу ягодник* — урманда җиләкле урынны табу; *колхозные ягодники* — колхозның җиләк-җимеш бакчалары; 2. җиләк куагы, җиләк бирә торган үсемлек; 3. *обл.* җиләктән хәзерләнгән ашамлык яки эчемлек; 4. *разг.* җиләк яратучы, җиләк ашарга яратучы; 5. җиләк сатучы, җиләк белән сату итүче.

**Я'ГОДНИЦА** *ж.*— к. ягодник 4, 5.

**Я'ГОДНЫЙ** — 1. җиләк ...-ы, җиләкле; *ягодный запах* — җиләк исе; *ягодный год* — җиләкле ел; 2. җиләк ...-ы, җиләк бирүче; *ягодный куст* — җиләк куагы; *ягодные растения* — җиләк бирүче үсемлекләр; 3. җиләк ...-ы, җиләктән хәзерләнгән; *ягодный пирог* — җиләк бәлеше; *ягодное вино* — җиләктән хәзерләнгән аракы.

**ЯГУА'Р** *м.*— ягуар (ерткыч хайван).

**ЯГУА'РОВЫЙ** — ягуар ...-ы; *ягуаровая шкура* — ягуар тиресе.

**ЯГУ'РТ** *м.*— к. югурт.

**ЯД** *м.*— 1. агу; *принять яд* — агу йоту, агу эчү; 2. *перен.* зәһәр, агу, мәкер; *письмо, полное яду* — зәһәр белән тулган хат, агулы хат.

**Я'ДЕРНЫЙ** *спец.*— 1. төш ...-ы; *ядерный сок* — төш сыекчасы; 2. ядрә...-ы; *ядерный вес* — ядрә авырлыгы; 3. *физ.* атом төше ...-ы, атом ядросы ...-ы; *ядерная физика* — атом төше физикасы; 4. *биол.* күзәнәк төше ...-ы; *ядерная структура бацилл* — бациллаларда күзәнәк төше структурасы.

**ЯДОВИ'ТОСТЬ** *ж. мн.* нет — агулылык, агулы булу; зәһәрлелек, зәһәрле булу.

**ЯДОВИ'ТЫЙ** — 1. агулы, агулагыч, агулый торган; *ядовитое вещество* — агулы матдә; *ядовитая змея* — агулы елан; 2. *перен.* зәһәрле, ачы телле, агулы, мәкерле; *ядовитый человек* — зәһәрле кеше.

**ЯДОНО'СНЫЙ** — к. ядовитый 1.

**ЯДРЁНЫЙ** *простореч.* — 1. эре, яхшы сыйфатлы, тук; *ядрёное яблоко* — эре алма; 2. таза, нык, таза тәнле, тыгыз, тыгыз тәнле; *ядрёный старик* — таза карт; *ядрёная девка* — таза тәнле кыз; 3. саф, чиста, шифалы; *ядрёный воздух* — саф һава; 4. *обл.* күбекле, әчеп житкән, чемер-чемер итеп тора торган; *ядрёный квас* — әчеп житкән квас.

**ЯДРИ'ЦА гречиха-ядрица** *ж.* — эре карабодай ярмасы.

**ЯДРО'** *ср.* — 1. төш; *ядро ореха* — чикләвек төше; 2. үзәк, үзәк өлеш, эчке өлеш, төш; *ядро земли* — жирнең үзәге; *ядро древесины* — үзагачның үзәге; *ядро атома* — атом төше; 3. *перен.* нигез, асыл; *ядро проблемы* — проблеманың нигезе; *ядро вопроса* — мәсьәләнең асылы; 4. *перен.* төп өлеш, нигез, үзәк; *ядро организации* — оешманың нигезе; 5. ядрә (борынгы заманда туптан ату өчен коеп ясалган шар формасындагы снаряд).

**ЯДРО'ВЫЙ** *спец.* — 1. төш ...-ы, ядро ...-ы; *ядровая часть* — (берәр нәрсәнең) төш өлеше; 2. *спец.* эчке, үзәктәге. ◇ **Ядровое мыло** *спец.* — ядровый сабын (май кислоталары күп кертелгән яхшы сортлы сабын).

**Я'ЗВА** *ж.* — 1. яман шеш, яра, эренле яра, кутырлы җәрәхәт; *язва желудка* — ашказаны ярасы; 2. *устар.* үләт, үләт китерә торган авыру (чума һ. б.); 3. *перен.* яманлык, явызлык, бәла; 4. *перен. разг. фам.* ачы телле кеше, зәһәр телле кеше, мәкерле кеше, зәһәре чыккан кеше. ◇ **Моровая язва** — үләт. **Сибирская язва** — түләмә.

**Я'ЗВЕННИК** *м.* — 1. *бот.* куян кәрешкәсе (үсемлек); 2. ашказаны ярасы белән авыручы кеше.

**Я'ЗВЕННЫЙ** — яман шеш ...-ы, эренле яра ...-ы, җәрәхәт ...-ы, кутырлы җәрәхәт...-ы, яра...-ы; *язвенные следы* — җәрәхәт эзләре.

**Я'ЗВИНА** *ж* — 1. китек урын, китек, кителеп беткән урын, сыр; *язвины на ноже* — пычак йөзендә кителеп беткән урыннар, пычак йөзендәге сырлар; 2. яра эзе, җәрәхәт эзе; *язвины на коже* — тиредәге яра эзләре; 3. *разг.* зур яман шеш, яман җәрәхәт; 4. *устар.* өн (җәнлек өне).

**ЯЗВИ'ТЕЛЬНОСТЬ** *ж. мн.* нет — зәһәрлелек, зәһәр булу, чәнечкеле булу, чәнчү; *говорить с язвительностью* — чәнчеп сөйләү.

**ЯЗВИ'ТЕЛЬНЫЙ** — зәһәрле, зәһәр, чәнечкеле; *язвительное замечание* — зәһәрле искәртү; *язвительный человек* — зәһәрле кеше, зәһәр телле кеше.

**ЯЗВИ'ТЬ** — 1. *устар. (ранить)* яралау, җәрәхәтләү; 2. *перен. устар. поэт. (причинять боль)* әрнетү, җанны кыю, җәфалау; 3. *перен. простореч. устар. (бранить, поносить)* чәнечкеле (зәһәр) сүзләр әйтеп әрләү, сүгү, орышу, тиргәү; 4. *(говорить язвительно)* чәнчеп сөйләү, әче тел белән сөйләү, төрттереп сөйләү, зәһәр тел белән сөйләү; *язвить на чей-нибудь счёт* — берәүгә төрттереп сөйләү.

**Я'ЗЕВЫЙ** — 1. бәртәс ...-ы, опты ...-ы; *язевая икра* — бәртәс икрасы; 2. бәртәс балыгыннан хәзерләнгән; *язевая уха* — бәртәс балыгыннан хәзерләнгән шулпа, бәртәс шулпасы.

**ЯЗЫ'К** *м.* — 1. тел; *коровий язык* — сыер теле; *лишаться языка* — телдән язу; *родной язык* — туган тел; *литературный язык* — әдәби тел; *у него злой язык* — ул бик әче телле; 2. *старин.* халык; *нашествие двунадесяти языков* (о войне 1812 года) — унике телдә сөйләшүче халыкларның яу булып килүе; 3. тел (кирәкле мәгълүматлар алу өчен дошман гаскәрләре эченнән разведчиклар тотып алып кайткан әсир); 4. кыңгырау теле. ◇ **Высуня язык** — телен салындырып, тирләп-пешеп, ах-вах килеп. **Держать язык за зубами** — телне тыю, күп сөйләнмәү, күп сөйләмәү. **Длинный язык** *перен.* — озын тел, куыш авыз, бик күп сөйләүчән кеше. **Закусить язык** — к. прикусить язык. **Злые языки** *перен.* — усал телләр, гайбәтчеләр, яла ягучылар; *всё это злые языки говорят* — боларның барын да усал телләр сөйлиләр. **На язык** — телгә, телдә; *остр на язык* — телгә үткен. **Общий язык** — уртак тел; *найти общий язык с кем-нибудь* — берәр кеше белән уртак тел табу. **Придержать язык** *разг.* — телне тыеп тору, сөйләми тору. **Прикусить язык** *разг.* — телне тыеп калу, нәрсәне дә булса әйтүдән тыелып калу. **Проглотить язык** — телне йоту; *почему молчишь, язык что-ли проглотил?* — нигә бернәрсә дә сөйләмисең, телеңне йоттыңмы әллә? **Развязать язык** — телен ачып җибәрү, сөйләтү, сөйләргә мөмкинлек тудыру. **Сорвалось с языка** *разг.* — телдән ычкынды. **Тянуть или дёргать за язык** *разг.* — көчләп сөйләтү, теленнән тартып сөйләтү; *никто тебя за язык не тянет* — беркем дә сине көчләп сөйләтми. **Хорошо привешенный или подвешенный язык** — телгә оста булу, сөйләргә оста булу, әйбәт итеп сөйли алу; *у него язык хорошо подвешен* — ул телгә оста. **Язык без костей** *перен. разг.* — телнең сөяге юк (артык сүз сөйләүче кеше турында). **Языки пламени или огненные языки** — ялкын телләре (биеккә күтәрелеп янган ут турында). **Язык не повернётся сказать** — әйтергә тел бармый, әйтергә тел әйләнми. **Языком трепать** *разг.* — чүбек чәйнәү, буш сүз сөйләп вакыт уздыру, ләчтит сату. **Язык проглотишь** — телеңне йотарсың, бик тәмле. **Язык развязался** — теле (м, н) ачылды, сөйли башлады (м, н). **Язык чесать** *разг.* — к. языком трепать. **Язык чешется** *разг.* — тел (м.н) кычытып тора (нәрсә дә булса әйтергә).

**ЯЗЫКА'СТЫЙ** *простореч. фам.* — үткен телле, усал телле; тел бистәсе.

**ЯЗЫКОВЕ'Д** *м.* — тел галиме, тел белгече, телче, тел белеме галиме.

**ЯЗЫКОВЕ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — тел белемә.

**ЯЗЫКОВЕ'ДНЫЙ** — к. языковедческий.

**ЯЗЫКОВЕ'ДЧЕСКИЙ** — тел белеме ...-ы, тел белеменә караган; *языковедческие дисциплины* — тел белеме дисциплиналары.

**ЯЗЫКОВО'Й** — тел ...-ы; *языковая система* — тел системасы.

**ЯЗЫКО'ВЫЙ** — 1. тел...-ы; *языковые мышцы* — тел мускуллары; 2. телдән хәзерләнгән; *языковая колбаса* — телдән хәзерләнгән колбаса.

**ЯЗЫКОЗНА'НИЕ** *ср. мн.* нет — к. языковедение.

**ЯЗЫКОТВО'РЧЕСКИЙ** *лингв. лит.* — тел иҗаты ...-ы; *языкотворческая деятельность* — тел иҗаты эшчәнлеге.

**ЯЗЫКОТВО'РЧЕСТВО** *ср. лингв. лит.* — тел иҗаты.

**ЯЗЫ'ЧЕСКИЙ** — мәҗүсиләр ...-ы, мәҗүсилек ...-ы; *языческая религия* — мәҗүсиләр дине.

**ЯЗЫ'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет — мәҗүсилек (потка табыну, бик күп төрле аллаларга табынуга нигезләнгән дин).

**ЯЗЫ'ЧНИК** *м.*, **ЯЗЫ'ЧНИЦА** *ж.* — 1. мәҗүси, потка табынучы; 2. *простореч.* күп телләрне белүче, күп телләрдә сөйләшүче кеше.

**ЯЗЫ'ЧНЫЙ** — 1. тел ...-ы; *язычные мышцы* — тел мускуллары; 2. *лингв.* тел ...-ы, тел катнашы белән ясала торган; *язычные согласные* — тел тартыклары.

**ЯЗЫЧО'К** *м.* — 1. тел; *злой у него язычок!* — усал да соң аның теле! *язычок колокольчика* — кыңгырау теле; *язычок замка* — йозак теле; 2. *анат.* кече тел; 3. *бот.* кыякча, кыякчык.

**ЯЗЬ** *м.* — бәртәс, опты (балык).

**ЯИ'ЦКИЙ** *истор.* — Җаек ...-ы; *яицкие казаки* — Җаек казаклары.

**Я'ИЧНИК** *м.* — 1. *анат.* күкәйлек, аналык бизе; 2. күкәй сатучы, йомырка сатучы.

**ЯИ'ЧНИЦА** *ж.* — 1. йомырка тәбәсе, кудырылган йомырка; 2. к. яичник 2.

**ЯИ'ЧНЫЙ** — 1. йомырка ...-ы; *яичный белок* — йомырка агы; *яичная торговля* — йомырка сәүдәсе; 2. йомыркадан хәзерләнгән, йомырка ...-ы; *яичный порошок* — йомыркадан хәзерләнгән порошок, йомырка порошогы.

**ЯЙЛА'** *ж. мн.* нет — җәйләү (Кырым тауларында сарыклар көтү өчен файдаланыла торган урмансыз урыннар).

**ЯЙЦЕВИ'ДНЫЙ** — йомыркасыман, йомыркага охшаган; *яйцевидный камень* — йомыркага охшаган таш.

**ЯЙЦЕВО'Д** *м. анат.* — күкәй юлы.

**ЯЙЦЕВО'Й** *анат. бот.* — күкәй ..., күкәй ...-ы; *яйцевая клетка* — күкәй күзәнәк, күкәй күзәнәге.

**ЯЙЦЕЕ'Д** *м. зоол.* — күкәйашар (үз күкәйләрен башка бөҗәкләрнең күкәйләре эченә сала торган бөҗәк).

**ЯЙЦЕЗАГОТОВИ'ТЕЛЬНЫЙ** *спец.* — йомырка хәзерләү ...-ы; *яйцезаготовительная кампания* — йомырка хәзерләү кампаниясе.

**ЯЙЦЕЗАГОТО'ВКА** *спец.* — йомырка хәзерләү.

**ЯЙЦОКЛА'Д** *м. зоол.* — йомырка салгыч, күкәй салгыч (кайбер бөҗәкләрдә йомырка салу органы).

**ЯЙЦЕКЛАДУ'ЩИЙ** *зоол.* — к. яйцеродный.

**ЯЙЦЕКЛЕ'ТКА** *ж. биол.* — күкәй күзәнәк (аналык җенес күзәнәге).

**ЯЙЦЕМЯСНО'Й** *с.-х.* — йомырка һәм ит бирә торган, йомырка һәм ит бирүче; *яйцемясные породы кур* — тавыкларның йомырка һәм ит бирә торган токымнары.

**ЯЙЦЕНО'СКИЙ** *с.-х.* — йомырканы күп салучы, күкәйне күп салучы; *яйценоские породы кур* — йомырканы күп салучы тавык токымнары.

**ЯЙЦЕНО'СКОСТЬ** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — йомырка салучанлык, күкәй салучанлык; *средняя яйценоскость породистых кур* — нәселле тавыкларның уртача йомырка салучанлыгы.

**ЯЙЦЕОБРА'ЗНЫЙ** — к. яйцевидный.

**ЯЙЦЕРО'ДНЫЙ** *зоол.* — күкәйдән тудыручы; *яйцеродные млекопитающие* — күкәйдән тудыручы имезүчеләр.

**ЯЙЦО'** *ср.* — 1. *биол.* (*женская половая клетка*) күкәй күзәнәк; 2. йомырка, күкәй; *утиное яйцо* — үрдәк йомыркасы; *муравьиные яйца* — кырмыска йомыркалары; 3. йомыркага охшатып эшләнгән әйбер, йомырка формасындагы әйбер; *хрустальное яйцо* — йомыркага охшатып эшләнгән хрусталь, хрусталь йомырка. ◇ **Выеденного яйца не стоит** — сукыр бер тиен дә тормый (бернинди дә әһәмияте юк, бөтенләй әһәмиятсез).

**ЯК** *м.* — як (Үзәк Азиядә һәм Тибетта яшәүче озын йонлы, мөгезле хайван).

**Я'КАТЬ** *несов.* — 1. „я"лаштыру, „я"лаштырып сөйләү (аерым сүзләрдә басымсыз „е" авазы урынына „я" авазы куллану; мәсәлән, „весна" урынына „вясна"); 2. *разг. фам. шутл.* мин-минләнү (сөйләгәндә „мин" сүзен күп кулланып, үзең турында кирәгеннән артык белдереп тору).

**Я'КО** *союз. книж. церк. устар.* — буларак, булганлыктан, чөнки; *лакей Готлиб, яко немец, получал с едой четыреста восемьдесят рублей в год* (Салтыков-Щедрин) — хезмәтче Готлиб, немец булганлыктан, елына ашаудан тыш дүрт йөз сиксән сум ала иде.

**ЯКОБИ'НЕЦ** *м. истор.* — якобинец, якобинчы (революционер-демократ, 1789 елгы француз революциясе чорында Париждагы радикал политик клуб әгъзасы).

**ЯКОБИ'НСКИЙ** *истор. полит.* — якобинецлар...-ы, якобинчылар...-ы; якобинчылык...-ы; *якобинская диктатура* — якобинчылар диктатурасы.

**ЯКОБИ'НСТВО** *ср. мн.* нет, *истор. полит.*— якобинчылык (якобинчыларның политик принциплары һәм эшчәнлекләре).

**Я'КОБЫ — 1.** *союз. книж. устар. разг. ирон.*— ... дип, ... имеш дип; *говорили, якобы вы уехали* — сезне киткән имеш дип сөйләгәннәр иде; **2.** *частица, книж.* имеш, имештер, гүяки, янәсе.

**Я'КОРНЫЙ** — 1. якорь...-ы; *якорная цепь* — якорь чылбыры; 2. якорьда тору...-ы; *якорная стоянка* — якорьда тору урыны.

**Я'КОРЬ** *м.*— якорь (1. *мор.* судноны бер урында тотып тору өчен су төбенә төшерелә торган җайланма; *отдать якорь* — якорь төшерү; *стоять на якоре* — якорьда тору; 2. *тех.* к. ротор 1; 3. *тех.* сәгать механизмының йөрешен көйләүче деталь). ◇ **Якорь магнита** *тех. физ.*— магнит якоре (магнит полюсларына тартылучы тимер кисәге). **Якорь спасения** — теге яки бу хәлдән котылуның соңгы чарасы, соңгы өмет, соңгы таяныч.

**ЯКУ'ТКА** *ж.*— якут хатын-кызы.

**ЯКУ'ТСКИЙ** — якут...-ы, якутлар...-ы; *якутский язык* — якут теле.

**ЯКУ'ТЫ** *мн.*— якутлар, якут халкы (Якутия АССРның төп халкы).

**ЯКША'ТЬСЯ** *несов. просторeч.*— аралашу, дуслашу, дус булып йөрү (гадәттә очраклы кешеләр белән).

**ЯЛ** *м. мор.*— ял, каек (1. хәрби корабльләрдә дүрт ишкәкле көймә; 2. ике мачталы җилкәнле судно).

**Я'ЛИК** *м.*— ялик, каек, кечкенә көймә (гадәттә елга аркылы чыгу өчен файдаланыла торган ике яки дүрт ишкәкле көймә).

**Я'ЛИЧНИК** *м.*— каекчы, көймәче.

**Я'ЛИЧНЫЙ — 1.** ялик...-ы, каек...ы, кечкенә көймә...-ы; *яличные вёсла* — каек ишкәкләре; 2. ялик белән ..., каек белән..., кечкенә көймә белән ...; *яличная переправа* — каек белән елга аркылы чыгу (чыгару).

**Я'ЛОВЕТЬ** *несов. с.-х.*— кысыр калу.

**Я'ЛОВИЦА** *ж. с.-х. обл.*— к. яловка 1.

**Я'ЛОВИЧНЫЙ** *спец.*— сыер күненнән тегелгән, сыер күненнән эшләнгән; *яловичные голенища* — сыер күненнән тегелгән итек кунычлары.

**Я'ЛОВКА** *ж.*— 1. *с.-х. обл.* кысыр сыер; тана; 2. *спец.* сыер тиресе (бер яшь ярымнан картрак сыер тиресе).

**Я'ЛОВОСТЬ** *ж. мн.* нет, *с.-х.*— кысыр калучылык, кысырлык, кысыр калу; *ликвидация яловости у коров* — сыерларның кысыр калучылыгын бетерү.

**Я'ЛОВЫЙ** *с.-х. спец.*— 1. кысыр; *яловый скот* — кысыр терлек; *яловые земли* — кысыр җирләр (сөрелмичә ял иттерелә торган җирләр); *яловый крыжовник* — кысыр крыжовник; 2. сыер тиресеннән эшләнгән, сыер күненнән эшләнгән (тегелгән), кызыл күннән эшләнгән (тегелгән); *яловая кожа* — сыер тиресеннән эшләнгән күн; *яловые сапоги* — сыер күненнән тегелгән итек.

**ЯМ** *м. истор.*— ям өе (элек ерак юлга чыккан кешеләрнең атларын алмаштыру өчен билгеләнгән почта станциясе).

**Я'МА** *ж.*— 1. баз, чокыр; *картофельная яма* — бәрәңге базы; *силосная яма* — силос базы; 2. *перен.* иңкүлек, иңкү урын, уйсулык, уйсу урын; *город расположен в яме* — шәһәр иңкүлектә урнашкан; 3. *перен. устар.* зиндан, төрмә, баз; *посадить в яму* — зинданга утырту; 4. *перен. неодобр.* бозыклык оясы. ◇ **Воздушная яма** *ав.*— һава чокыры (һаваның очучы аппаратларны кинәт түбән төшеп китәргә мәҗбүр итә торган башка температурадагы катлавы). **Волчья яма** *воен.*— бүре базы (җир астына яшерелгән баз рәвешендәге ясалма тоткарлык, киртә). **Рыть яму** *перен.*— кемгә дә булса начарлык, усаллык эшләргә омтылу, кемгә дә булса баз казу; *не рой другому ямы, сам в неё попадёшь* (поговорка) — кешегә баз казыма, үзең төшәрсең.

**ЯМБ** *м. лит.*— ямб (басымы икенче иҗектә булган ике иҗекле шигырь стопасы).

**ЯМБИ'ЧЕСКИЙ** *лит.*— ямб белән язылган, ямблы; *ямбические стихи* — ямб белән язылган шигырьләр; *ямбическая стопа* — ямблы стопа.

**ЯМБОХОРЕ'Й** *м. лит.*— ямбохорей, ямб һәм хорей (ямб һәм хорей белән язылган дүрт иҗекле шигырь стопасы).

**Я'МИНА** *ж. разг.*— 1. зур (тирән) чокыр, (зур) тирән баз; 2. зур иңкүлек.

**Я'МИСТЫЙ** *разг.*— чокырлы-чакырлы, чокырлы, чокырланып беткән.

**Я'МИЩА** *ж. разг. увелич.*— 1. зур (тирән) чокыр, зур (тирән) баз; 2. зур иңкүлек.

**Я'МКА** *ж.*— 1. кечкенә чокыр, кечкенә баз; 2. чокыр, чокырчык; *ямки на щеках при улыбке* — елмайганда биттә барлыкка килгән чокырчыклар; *глазная ямка* — күз чокыры; *слуховая ямка* — ишетү чокыры (кайбер түбән төзелешле хайваннарда).

**ЯМСКО'Й** *истор.*— ямщиклар...-ы, ямщик...-ы, ямчылар...-ы, ямчы...-ы; ям чабу...-ы, ямчылык...-ы, атлы почта йөртү...-ы; *ямская слобода* — ямщиклар бистәсе; *ямская повинность* — ям чабу йөкләмәсе.

**ЯМЩИ'К** *м.*— ям чабучы, ямщик, ямчы.

**Я'МЩИНА** *ж. мн.* нет, *истор.*— 1. ям чабу, ямщиклык, ямщиклык итү, ямчылык, ямчылык итү, атлы почта йөртү; 2. ям чабу йөкләмәсе, ямщиклык йөкләмәсе, ямчылык йөкләмәсе, атлы почта йөртү йөкләмәсе.

**ЯМЩИ'ЦКИЙ** — ямщиклар...-ы; ямщик...-ы; ямщиклык...-ы, ямщикларга хас; *ямщицкие лошади* — ямщик атлары; *ямщицкие повадки* — ямщикларга хас гадәтләр.

**ЯНВА'РСКИЙ** — *январь...-ы*; *январские холода* — январь суыклары.

**ЯНВА'РЬ** *м.*— январь, январь ае.

**Я'НКИ** *м. нескл.*— янки, янкилар (европалылар тарафыннан АКШта туган америкалыларга бирелгән кушамат).

**ЯНТА'РНЫЙ — 1.** гәрәбә..., гәрәбәдән эшләнгән; *янтарный мундштук* — гәрәбә мундштук; *янтарное запястье* — гәрәбә-

дән эшләнгән беләзек; 2. ачык сары; *янтарный цвет* — ачык сары төс.

**ЯНТА'РЬ** *м.* — гәрәбә (төрле бизәкле әйберләр эшләгәндә файдаланыла торган үтә күренмәле сары яки көрән-сары төстәге казылма матдә).

**Я'НУС: двуликий Янус** *книж.* — к. двуликий.

**ЯНЫЧА'РСКИЙ** — янычарлар...-ы, янычар...-ы; янычарларга хас, янычарларча...; *янычарский отряд* — янычарлар отряды.

**ЯНЫЧА'РЫ** *мн.* — янычарлар (солтан Төркиясендә үзенә аерым хокуклар белән файдаланган җәяүле гаскәрләр).

**ЯПО'НКА** *ж.* — япон хатын-кызы.

**ЯПО'НСКИЙ** — 1. япон...-ы, японнар...-ы; японнарга хас; *японский язык* — япон теле; *японская одежда* — японнарга хас кием.

**ЯПО'НЦЫ** *мн.* — японнар, япон халкы (Япониянең төп халкы).

**ЯР** I *м. обл.* — 1. текә яр; 2. агачлар үскән тирән чокыр.

**ЯР** II *м. мн.* нет, *обл. спец.* — яр авыруы (аталану чорында кошларда була торган авыру).

**ЯРД** *м.* — ярд (1. Англиядә 0,91 сантиметрга тигез булган озынлык үлчәве; 2. Англиядә 1,2 акрга тигез булган мәйдан үлчәве).

**ЯРЕ'М** *м. книж.* — к. ярмо.

**ЯРЕ'МНЫЙ** *устар.* — агач камытка жигелеп эшли торган. ◇ **Яремные вены** *анат.* — баш яки бит өлешеннән таралып киткән кара кан тамырлары.

**ЯРИ'ТЬСЯ** *несов.* — 1. *устар. (быть в гневе, ярости)* шашыну, шашу, котырыну, котыру, кызу, ярсу, ачулану; 2. *спец. обл.* женси уяну (хайваннарда).

**Я'РИЦА** *ж. обл.* — к. ярь I.

**Я'РКА** *ж.* — шешәк сарык, бәрән сарык, ярка.

**Я'РКИЙ** — 1. якты, яп-якты, күз чагылдыргыч; *яркое солнце* — якты кояш; *яркий снег* — күз чагылдыргыч кар; 2. ачык, күзгә бәрелеп торган; *яркий цвет* — ачык төс; 3. *устар.* ачык, яңгыравыклы; *яркий голос* — ачык тавыш; 4. *перен.* ачык, күзгә бәрелеп торган, көчле; *яркий талант* — күзгә бәрелеп торган талант; *яркий пример* — ачык мисал; *яркое чувство* — көчле хис.

**Я'РКОСТЬ** *ж. мн.* нет — 1. яктылык; *яркость огня* — утның яктылыгы; 2. ачыклык; *яркость красок* — буяуларның ачыклыгы; 3. көчлелек; *яркость таланта* — талантның көчлелеге.

**ЯРЛЫ'К** *м.* — ярлык (1. *истор.* татар ханнарының боерык язуы; *ярлык хана Сахиб-Гирея* — Сахибгәрәй ханның ярлыгы; 2. товарның исеме, авырлыгы, саны, бәясе һ. б. язылып, товар өстенә ябыштырылган кәгазь; *ярлык на бутылке* — шешәгә ябыштырылган ярлык; 3. зерым келәймә, билге һ. б. төшерелгән кәгазь; *аптечный ярлык* — аптека ярлыгы; 4. *перен. разг. пренебр.* к. этикетка 2).

**Я'РМАРКА** *ж.* — ярминкә; *колхозная ярмарка* — колхоз ярминкәсе.

**Я'РМАРОЧНЫЙ** — ярминкә...-ы; ярминкәдә була торган; *ярмарочный комитет* — ярминкә комитеты; *ярмарочный балаган* — ярминкә кәмите.

**ЯРМО'** *ср.* — 1. агач камыт, үгез камыты; *волы под ярмом* — агач камытка жигелгән үгезләр; 2. *перен. книж. только ед.* золым, җәбер-золым, кысу, изү, авырлык; *советский человек свободен от ярма капитализма* — совет кешесе капитализм золымыннан азат.

**Я'РМОНКА** *ж. устар. простореч.* — к. ярмарка.

**ЯРОВИЗА'ТОР** *м. с.-х.* — яровизатор, яровойлаштыручы; *курсы яровизаторов* — яровизаторлар курсы.

**ЯРОВИЗА'ЦИЯ** *ж. мн.* нет, *с.-х.* — яровойлаштыру (үсеп чыгу һәм өлгерү процессын тизләтү өчен орлыкларны махсус рәвештә эшкәртү); *яровизация семян* — орлыкларны яровойлаштыру.

**ЯРОВИЗИ'РОВАННЫЙ** *с.-х.* — яровойлаштырылган.

**ЯРОВИЗИ'РОВАТЬ** *сов.* и *несов. с.-х.* — яровойлаштыру; *яровизировать семена ржи* — арыш орлыкларын яровойлаштыру.

**ЯРОВИЗИ'РОВАТЬСЯ** *сов.* и *несов.* — яровойлашу; *изменять температуру яровизирующегося зерна* — яровойлашучы орлыкның температурасын үлчәү.

**ЯРОВО'Е** *в знач. сущ.* — сабан ашлыгы; *уборка яровых* — сабан ашлыкларын урып-җыю.

**ЯРОВО'Й** — 1. яз көне чәчелә торган; *яровая пшеница* — яз көне чәчелә торган бодай; 2. сабан ашлыгы...-ы; *яровая солома* — сабан ашлыгы саламы; 3. сабан...-ы, сабан ашлыгы чәчелә торган; *яровое поле* — сабан басуы, сабан ашлыгы чәчелә торган басу.

**Я'РОСТНЫЙ** — ярсулы, ярсыган, ачулы, гайрәтле, котырынган; *яростный взгляд* — ярсулы караш; *яростная атака* — ярсулы атака.

**Я'РОСТЬ** *ж. мн.* нет — ярсу, ачу, котырыну, гайрәтләнү; *ярость волн* — дулкыннар ярсуы.

**ЯРУНО'К** *м. стол.* — ярунок (45°лы почмак ясап тоташтырылган ике пластинкадан торган почмаклык).

**Я'РУС** I — 1. кат, ярус; *уложить мешки в три яруса* — капчыкларны өч кат итеп өю; 2. ярус; *ложа второго яруса* — икенче ярус ложасы; 3. *обл.* кат (агач бинада); *дом в два яруса* — ике катлы йорт; 4. *геол.* катлам, ярус (җир кабыгы катламы).

**Я'РУС** II *м. спец.* — ярус (Ак диңгез балыкчыларында тәрәч балыгы тоту өчен кармаклар тагылган берничә чакрым озынлыгындагы бау).

**Я'РУСНЫЙ** I — яруслап, кат-кат, кат-кат булып..., катлау-катлау, катлау-катлау булып...; *ярусное расположение* — катлау-катлау булып урнашу.

**Я'РУСНЫЙ** II *спец.*— ярус...-ы; ярус белән...-ы; *ярусные крючки* — ярус кармаклары; *ярусный лов* — ярус белән балык тоту.

**ЯРУ'ТКА** *ж. бот.*— ярут (чүп үлән).

**ЯРЫ'ГА** *м.*— **1.** *истор.* ярыга (полициядә эшләүче түбән чинлы кеше); **2.** *простореч. устар.* әчкече, юлдан язган кеше.

**ЯРЫ'ЖКА** *м.*— к. ярыга.

**ЯРЫ'ЖНИК** *м. простореч. устар.*— к. ярыга 2.

**ЯРЫ'ЖНЫЙ** — **1.** *истор.* ярыга ...-ы; ярыгалар ...ы; ярыгаларга хас; **2.** *простореч. устар.* юлдан язган, юлдан язган кешеләргә хас.

**Я'РЫЙ** — **1.** *книж.* к. яростный; **2.** ялкынлы, бик нык бирелгән; *ярый сторонник музыки* — музыканың ялкынлы тарафдары; **3.** саф, ялтырап тора торган; *ярый воск* — саф балавыз, ялтырап тора торган балавыз.

**ЯРЬ** I *ж. мн.* нет, *обл.*— сабан ашлыгы.

**ЯРЬ** II: **ярь-медянка** *ж. мн.* нет — ярь (бакырны күгәртеп ясала торган яшел буяу).

**ЯСА'К** *м. истор.*— ясак (Москва Русенда һәм патша Россиясендә Идел буе, Себер һәм Ерак Көнчыгыш халыкларына натуралата түләр өчен билгеләнгән салым).

**ЯСА'ЧНЫЙ** *истор.*— **1.** ясак...-ы; *ясачные сборы* — ясак җыемнары; **2.** ясак түләүче, ясак түли торган; *ясачные люди* — ясак түләүче кешеләр.

**Я'СЕЛЬНИЧИЙ** *м. истор.*— ясельничий (Москва Русенда ат абзарлары белән идарә итү приказы начальнигы).

**Я'СЕЛЬНЫЙ** — **1.** утлык...-ы; *ясельная решётка* — утлык рәшәткәсе; **2.** ясле...-ы; ясләләр...-ы; *расширение ясельной сети в колхозах* — колхозларда ясләләр челтәрен киңәйтү.

**Я'СЕНЕВЫЙ** — **1.** корычагач...-ы; дардар агачы...-ы; *ясеневый лист* — корычагач яфрагы; **2.** корычагачтан эшләнгән, дардар агачыннан эшләнгән; *ясеневая мебель* — корычагачтан эшләнгән мебель.

**Я'СЕНЕЦ** *м. бот.*— ясенец (корычагачныкы кебек каурыйсыман яфраклы, эфир майлары аерып чыгара торган күпьеллык үсемлек).

**Я'СКА** *ж. обл.*— ләтчә (җәнлек).

**ЯСКО'ЛКА** *ж. бот.*— ясколка (канәферчәләр семьялыгына караган ак чәчәкле, тар яфраклы үсемлек).

**Я'СЛИ** *ед.* нет — **1.** *(кормушка для скота)* утлык; **2.** *(воспитательное учреждение)* ясле; *заводские ясли* — завод яслесе.

**ЯСМИ'Н** *м. устар.*— ясмин (гөл).

**ЯСМИ'ННЫЙ**, **ЯСМИ'НОВЫЙ** *устар.*— ясмин...-ы; *ясминовый запах* — ясмин исе.

**ЯСНЕ'ТЬ** *несов.*— ядтыру, яктыра бару; ачылу, ачыла бару; аязу, аяза бару; ачыклану, ачыклана бару.

**ЯСНОВЕЛЬМО'ЖНЫЙ** *истор., теперь ирон.*— галиҗәнап, олуг, олуг ихтирамлы, олуг ихтирам ителүче (элекке заманда Польша паннарын һәм Украина гетманнарын дәрәҗәләү һәм хөрмәтләү өчен әйтелгән сүз).

**ЯСНОВИ'ДЕНИЕ** *ср. мн.* нет — **1.** *религ.* гаептән хәбәр бирү, кәрамәт; **2.** *(прозорливость)* алдан күрү, алдан күрүчелек, алдан ук белеп тору, үткен акыллылык, үткен акыллы булу.

**ЯСНОВИ'ДЕЦ** *м.*, **ЯСНОВИ'ДИЦА** *ж.*— алдан белүче, алдан күрүче кеше, алдан күрү (белү) сәләтенә ия булган кеше, үткен акыллы кеше.

**ЯСНОВИ'ДЯЩИЙ** — алдан күрүче, алдан белүче, алдан күрә алу сәләтенә ия булган, үткен акыллы.

**Я'СНОСТЬ** *ж. мн.* нет — **1.** ачыклык, аныклык, аңлаешлылык, төзеклек; *внести ясность во что-нибудь* — берәр нәрсәгә ачыклык кертү.

**ЯСНО'ТКА** *ж. бот.*— баллы баба (чүп үлән).

**Я'СНЫЙ** — **1.** якты; *ясный месяц* — якты ай; **2.** *простореч.* ялтырап торган, ялтырап тора торган, чистартылган; *ясный самовар* — ялтырап торган самовар; **3.** ачык, аермачык (ишетелә, күренә, сизелә торган һ. б.); *ясные очертания гор* — тауларның ачык күренә торган сызыклары; **4.** аяз, якты, ачык, болытсыз (һава, күк турында); *ясный день* — аяз көн; *ясное небо* — якты күк (йөзе); болытсыз күк (йөзе); **5.** *перен. книж.-поэт.* саф, чиста, пакь, керсез, якты; *в ясных глазах светилась печаль* — аның саф күзләрендә моңсулык балкып тора иде; **6.** ачык аңлаешлы, җинел аңлаешлы, ачык; *ясные мысли* — ачык аңлаешлы фикерләр, ачык фикерләр; *ясное изложение*— ачык аңлаешлы язу (сөйләү); *ясное доказательство* — ачык дәлил; **7.** ачык, шөбһәсез, билгеле; *дело-то ясное* —мәсьәлә ачык; *ясное намерение* — ачык теләк; *ясно, что он солгал* — аның алдаганы билгеле. ◇**Ясное дело** *разг.* — шик юк, һичшиксез, сөйләп торасы да юк,әлбәттә; *ясное дело, мы правильно сделали* — сөйләп торасы да юк, без дөрес эшләгәнбез. **Ясный сокол** (соколик) *нар.-поэт.*— асыл егет, асыл кош; *приезжай ты к нам, соколик мой ясный* (Пушкин) — кил син безгә, асыл кошым минем.

**Я'СОЧКА** *м.* и *ж. разг. фам.*— акыллым, сөеклем, бәгырем, алтыным; *ясочка ты моя* — акыллым син минем.

**ЯСТА'К** *м. спец.*— к. ястык.

**ЯСТА'ЧНЫЙ** *спец.*— к. ястычный.

**Я'СТВО** *ср. устар. книж., теперь ирон.*— ашамлык, ашамлык әйберләр, нигъмәт, төрле нигъмәтләр.

**Я'СТРЕБ** *м.*— карчыга. ◇ **Менять кукушку на ястреба** — к. менять.

**ЯСТРЕБЁНОК** *м.*— карчыга баласы.

**ЯСТРЕБИ'НЫЙ** — **1.** карчыга...-ы; *ястребиный клюв* — карчыга томшыгы; **2.** карчыга белән..., *ястребиная охота* — карчыга белән аулау; **3.** *перен.* зәһәр, ачулы, ерткычларча..., явыз; *ястребиный взгляд* — зәһәр караш; **4.** *перен.* ыргакланып торган, бөкре; *ястребиный нос* — бөкре борын.

**ЯСТЫ'К** *м. спец.*— ястык (**1.** балык эченнән ярысы белән алынган уылдык; **2.** уылдык сүрүе, уылдык ярысы).

**ЯСТЫ'ЧНЫЙ** *спец.* — ярылы, сүрүле, яры (сүрү) эчендәге, тазартылмаган, чистартылмаган; *ястычная икра* — ярылы икра.

**ЯТАГА'Н** *м.*— ятаган, кәкре хәнҗәр, төрек хәнҗәре.

**ЯТО'ВЬ** *ж.*, **ЯТО'ВЬЕ** *ср. обл.*— (елгада белуга, осётр кебек балыклар яши торган) чокыр, урын.

**ЯТРЫ'ШНИК** *м. бот.*— төер тамыр (үсемлек).

**ЯТЬ** *м.*—ять (борынгы рус телендә аерым аваз билгесе булган, соныннан „е" авазына туры килгән „Ѣ" хәрефенең исеме). ◇ **На ять** *простореч. фам.*— менә дигән итеп, бер дигән итеп, шәп итеп; *сделать на ять* — менә дигән итеп эшләү.

**Я'ХОНТ** *м.*— якут (асылташ).

**Я'ХОНТОВЫЙ** — якут..., якуттан эшләнгән; *яхонтовые серьги* — якут алка.

**Я'ХТА** *ж.*— яхта (1. җилкәнле спорт көймәсе; 2. җилкәнле, пар белән йөри торган яки моторлы кечкенә диңгез судносы).

**Я'ХТЕННЫЙ** *спец.*— яхта...-ы; *яхтенный спорт* — яхта спорты.

**ЯХТ-КЛУ'Б** *м.*— яхт-клуб (су спорты эшләре белән шөгыльләнә торган оешма).

**ЯХТ-КЛУ'БОВЕЦ** *м.*— яхт-клуб әгъзасы, яхт-клуб хезмәткәре.

**Я'ХТНЫЙ, Я'ХТОВЫЙ** *спец.*— к. яхтенный.

**ЯХТСМЕ'Н** *м. спорт.*— яхтсмен (яхтада су спорты белән шөгыльләнүче спортсмен).

**ЯЧА'ТЬ** *несов. обл.*— сыкранып ыңгырашу, сыкранып кычкыру.

**ЯЧЕ'ИСТЫЙ** *спец.*— тишекле-тишекле, вак тишекле, вак күзәнәкле; *ячеистый бетон* — вак күзәнәкле бетон.

**ЯЧЕ'ИТЬСЯ** *несов. спец. обл.*— ятьмә күзләрендә буталу, ятьмә күзәнәкләренә эләгү (балык турында).

**ЯЧЕ'ЙКА** *ж.*—1. к. ячея; 2. ячейка (а. берәр иҗтимагый оешманың башлангыч группасы; б. башлангыч партия оешмасының элеккеге исеме).

**Я'ЧЕСТВО** *ср. мн.* нет, *книж. ирон.*— мин-минлек, үз-үзеңне күтәрү, тар индивидуализм.

**ЯЧЕЯ'** *ж. спец.*—1. күзәнәк; *сотовая ячея* — кәрәз күзәнәге; 2. күз; *невод с частой ячеей* — еш күзле ятьмә.

**Я'ЧИЙ** — як ...-ы; *ячьи рога* — як мөгезләре.

**ЯЧМЕ'ННЫЙ** —1. арпа ...-ы; *ячменный колос* — арпа башагы; *ячменная мука* — арпа оны; 2. арпа ...-ы; арпа онынан пешерелгән; *ячменный хлеб* — арпа ипие.

**ЯЧМЕ'НЬ** I *м. мн.* нет — арпа.

**ЯЧМЕ'НЬ** II *м.*— арпа (күз кабагына чыга торган сызлавык.)

**Я'ЧНЕВИК** *м. обл.*— арпа кабартмасы, арпа коймагы.

**Я'ЧНЕВЫЙ** *обл.*— к. ячменный 1.

**Я'ЧНИК** *м. обл.*— к. ячневик.

**Я'ЧНЫЙ** *обл.*— к. ячневый.

**Я'ШМА** *ж.*— яшма (кварцның бер төре булган тау токымы).

**Я'ШМОВЫЙ** — яшма ...-ы; яшмадан ясалган; *яшмовая шкатулка* — яшма шкатулка.

**Я'ЩЕР** *м.*—1. *зоол.* ящер (Африкада яшәүче, кәлтә еланга охшаган имезүче хайван); 2. *обл. старин.* к. ящерица.

**ЯЩЕРЁНОК** *м.*—1. ящер баласы; 2. кәлтә баласы, кәлтә елан баласы.

**Я'ЩЕРИЦА** *ж.*— кәлтә, кәлтә елан.

**Я'ЩЕРИЧНЫЙ** — кәлтә ...-ы; кәлтә елан ...-ы; *ящеричный хвост* — кәлтә койрыгы.

**Я'ЩИК** *м.*— әрҗә, тартма, ящик. ◇ **Зарядный ящик** *воен.*—заряд ящигы (артиллериядә снарядлар ташу өчен файдаланыла торган йөк арбасы). ◇ **Откладывать в долгий ящик** — билгесез вакытка кичектерү, эшне озакка сузу. **Сыграть в ящик** *простореч. вульг.*— үлү, гүргә керү, аяк сузу.

**Я'ЩИЧНИК** *м. спец.*—тартма (әрҗә) ясау остасы, ящик ясаучы.

**Я'ЩИЧНЫЙ** — әрҗә ...-ы; тартма ...-ы; ящик ...-ы; *ящичная крышка* — әрҗә капкачы, тартма капкачы.

**Я'ЩУР** *м. мн.* нет — тилчә, ящур (сыерларда һәм дуңгызларда була торган авыру).

**Я'ЩУРНЫЙ** — тилчә ...-ы; тилчә авыруы ...-ы, ящур ...-ы, ящур авыруы ...-ы, тилчәгә хас, ящурга хас; *ящурные явления* — тилчә билгеләре, тилчәгә хас билгеләр.

# ЧИТ ТЕЛ СҮЗЛӘРЕ ҺӘМ ТӘГЪБИРЛӘРЕ

Рус телендә чит телләрдән кергән кайбер сүзләр һәм тәгъбирләр үзләренең шул телдәге әйтелешләрен саклап латин хәрефләре белән язылалар. Марксизм-ленинизм классикларының әсәрләрен, рус әдәбиятын татар теленә тәрҗемә иткәндә ул тәгъбирләр шул килеш калдырылалар. Шуның өчен бу тәгъбирләрне сүзлеккә кертеп, аларның аңлатмасын бирү кирәк табылды. Чит тел тәгъбиреннән соң җәяләр эчендә ул тәгъбирләрнең якынча әйтелешен күрсәтү өчен татарча транскрипциясе бирелде. Бу транскрипциядә түбәндәге шартлы билгеләр кулланылды: борынлаштырылган сузыклар „ң" хәрефе кушып (аң, оң, эң), французча *eu*, немецчә *ö* авазлары татарча *ө* хәрефе белән күрсәтелде.

## A

AB OVO (*аб ôво*) латин.— яңа баштан, иң баштан; *начнем ab ovo* (Пушкин)—яңа баштан башлыйк.

A CAPPELLA (*а капêлля*) ит. муз.: *петь a cappella*—аккомпанемент ярдәменнән башка хор белән җырлау.

AD ABSURDUM — к. reductio ad absurdum.

AD CALENDAS GRAECAS (*ад калéндас грêкас*) латин.— к. календы.

